# МУСА ҖАРУЛЛАҺ БИГИЕВ

фәнни-биографик җыентык

Казан
«Жыен» нәшрияты
2022

ББК 86.38
Б47

*Китап «Татнефть» Компаниясенең матди ярдәме белән нәшер ителде*

*«Шәхесләребез» сериясенә нигез салучы:*
Татарстан Фәннәр академиясе академигы, тарих фәннәре докторы
М. Г. Госманов

*Редколлегия:*
Р.И. Вәлиев (җаваплы мөхәррир), М.Б. Галиев, Р.К. Гатауллин
(Рәдиф Гаташ), Х.Й. Миңнегулов, Ф.М. Рәфыйков, И.Г. Һадиев

*Фәнни мөхәррире*
Дания Заһидуллина,
филология фәннәре докторы

*Автор-төзүче*
Айдар Хәйретдинов,
фәлсәфә фәннәре кандидаты

**Б47** Муса Җаруллаһ Бигиев : фәнни-биографик җыентык / авт.-төз.: Хәйретдинов А.Г. – Казан: Җыен, 2022. – 832 б. : илл. – («Шәхесләребез» сериясе)
ISBN 978-5-902783-55-8

Җыентык күренекле татар дин галиме, философ, тарихчы, җәмәгать эшлеклесе һәм сәясәтче Муса Җаруллаһ Бигиевнең (1875–1949) мирасын киң катлау укучыларга таныту, яңа эзләнүләргә этәргеч ясау нияте белән төзелде.

Китапта М. Бигиевнең биографиясе, чыганакларга нигезләнеп, өзлексез тарих кебек тәкъдим ителә. Шулай ук моңарчы хәзерге графикада дөнья күрмәгән һәм аз билгеле булган хезмәтләре, язмалары, хатлары, аңа багышланган мәкаләләр, үз язганнарының библиографик күрсәткече һәм фоторәсемнәр туплап бирелде.

Китап милли мәдәният тарихы һәм дин фәлсәфәсе белән кызыксынучылар өчен файдалы һәм кызыклы булыр дип исәплибез.

ББК 86.38

ISBN 978-5-902783-55-8

© «Җыен» фонды, 2022
© Хәйретдинов А.Г., 2022
© ТР ФА Ш. Мәрҗани исем. Тарих институты, 2022

# Кереш сүз

Аллаһның олуг рәхмәте йөзеннән кешеләргә юл күрсәтүче һәм үрнәк буларак җибәрелгән пәйгамбәребез Мөхәммәд галәйһис-саләт вә-с-сәлам әйтеп калдырган хәдисләрнең берсендә мөселманнарның диннәрен яңарту өчен Аллаһу Тәгаләнең һәр йөзъеллыкның башында бер мөҗәддид, ягъни яңартучы җибәреп торуы турында хәбәр ителә.

Рухларын һәм милли-мәдәни язмышларын ислам дине белән бәйләгән халыкларның тарихына игътибар белән карaганда, андый шәхесләрнең булганлыгы, чыннан да, расланамы икән? Әлбәттә, раслана. Мәсәлән, борынгы заманнарда дөньяга килеп, исламият дөньясында бәрәкәтле эз калдырган мөселман галимнәре арасында Гомәр ибне Габделгазиз (миладияи 682–720), имам Әбу Хәнифә, имам Әгъзам исемнәре белән дан казанган Әбу Хәнифә эн-Ногман ибне Сабит әл-Куфи (699–767), Әбу Мансур әл-Матуриди (870–944); Әбу Насыр әл-Фараби (870–951); Әбу әл-Хәсән Гали ибне Исмәгыйль әл-Әшгари (873–936), Әбу Гали ибне Сина (980–1037); Әбу Хәмид Мөхәммәд ибне Мөхәммәд әл-Газали әт-Туси (1058–1111), Фәхретдин Әбу Габдуллаһ Мөхәммәд ибне Гомәр әр-Рази (1149–1209), Тәкыйетдин Әбу әл-Фәтех Мөхәммәд ибне Гали әл-Куси (1228–1302), Җәлалетдин Әбу әл-Фазыл Габдеррахман ибне Әбу Бәкер әс-Сөйутый (1445–1505), Шаһ Вәлиуллаһ Дәһләви (1703–1762); Габденнасыйр Курсави (1776–1812); Шиһабетдин әл-Мәрҗани (1818–1889); Габделкаюм Насыйри (1825–1902) һәм санап бетергесез башкалар шундыйлардан.

Исемнәре телгә алынган санаулы һәм искә алынмыйча калган санаусыз олуг гыйлем ияләре ислам дине кырында чәчелгән хак иман, хөр акыл, ирекле ихтыяр, пакь вөҗдан орлыкларыннан үсеп чыккан уңыш үрнәкләре булып торалар. Югарыда телгә алынган голямәнең исемнәре гел гарәпчә булса да, нәселләре белән алар гарәпләр генә түгел, әлбәттә. Алар күпсанлы төркиләрдән, фарсылардан, башка милләт вәкилләреннән булган. Һәр яңа мөҗәддиднең чираттагы йөзъеллыкның нәкъ менә башында дөньяга килүе шарт түгел, чөнки йөзъеллык биредә инсан буыннарының тәмам алмашып, иске карашларга ия булган кешеләрнең бөтенләй яңа буын белән алмашуы өчен кирәк булган вакыт аралыгын белдерә. Хәдистә иң мөһим асыл – андый галимнәрнең ислам диненә, аның тәгълиматы вә фәлсәфәсенә, үсеше вә тәрәккыятенә кертәчәк өлешләредер. Шуңа күрә исламият тарихы унбиш гасыр тәшкил итсә дә, мөҗәддидләрнең саны унбиштән күпкә артып китә. Бу исәптән, Муса Бигиевнең Әбу Хәнифә кебек данлыклы галим турындагы фикерләре искә төшә: Әбу Хәнифәнең олуглыгы аның иртәнге намазны тәһарәт алмыйча укырга күнеккән булуында түгел, гәрчә мөселманнар бу кадәр тәкъвалыктан бик хушлансалар да[1]. Бигиев фикеренчә, Әбу Хәнифәне хөрмәт итү, аны бөек мөҗәддид галим итеп тану бу кешенең ислам җәмгыятен камилләштерүгә, аның үсешенә һәм тәрәккый итүенә керткән бәрәкәтле гыйльми һәм рухи хезмәте өчен булырга тиеш.

Бу китапта сүз Муса әфәнде Бигиев турында булачак. Үзенең гомерен мөселманнарны озак гасырларга сузылган рухи һәм фикри йокыларыннан уятуга багышлаган, бу юлда җанын фида кыйлган бәндә,– какшамас иман һәм хөр мөстәкыйль фикер иясе, тарихларда сирәк очрый торган киң карашлы һәм

[1] Иртәнге намазны тәһарәт алмыйча уку дигән гыйбарәнең тел төбе Әбу Хәнифәнең үтә дә тәкъвалы вә диндар бер мөселман буларак төннәрне уяу хәлдә, гыйбадәттә үткәреп, йокламыйча үткәрүенә кайтып кала, чөнки әгәр ул йоклаган булса, уянганнан соң, иртәнге намазны укыр өчен ул, иң әүвәл, тәһарәт алырга тиеш булыр иде.

тирән белемле галим, югары әхлак сахибы… Галим дигәннән – Муса әфәнде дин галиме генә түгел, ул риязый, ягъни төгәл фәннәрдә дә, табигать фәннәрендә дә үзен иркен тоткан, хәтта кешеләргә ачылган белем даирәсен «дини гыйлем», «дөньяви гыйлем» кебек ике тармакка аеруның дөрес түгеллеген аңлаткан. Аның фикеренчә, Аллаһ тәгалә адәм баласына акны – карадан, яхшыны яманнан аера белү хосусыятен биргән икән, кешенең бу юлдагы һәр табышы, һәр ачышы – дини табыш, дини ачыш, рухи казаныш була. Ул ачышларның яхшыларын кеше үз тормышында файдалана, начар нәрсәләрдән исә ваз кичә. Бу ысул һәм метод шәригать өчен дә, физика өчен дә, сәясәт өчен дә, әдәп-әхлак өчен дә һаман шул бер, һәммәсенә карата да кулланырлык үлчәү булып тора.

Бу җәһәттән искә алынган галимнәр белән бергә, Муса Җаруллаһ та мөҗәддид буларак кабул ителергә, танылырга, әлбәттә, лаек. Әмма аннан алдагы мөҗәддидләрнең мирасы күптән инде киң таралыш табып, исламиятнең рухи һәм дини мирасына әйләнеп, аның җисеменә һәм канына сеңгән булса, Муса әфәнденең рухи, гыйльми, әхлакый мирасын өйрәнү, аны тиешенчә аңлау һәм кабул итеп гамәлдә куллану, әлегә, киләчәктә эшләнәчәк эш булып тора, чөнки бөек татар дин галименең фикерләре һәм исламиятне аңлавы үзе яшәгән дәвереннән бик нык алга киткән булган. Аның мирасына, карашларына, табыш вә ачышларына, тәкъдимнәренә бәя бирә алу өчен генә дә кеше рухи яктан да, акыл ягыннан да, вөҗдан һәм әхлак ягыннан да җитешкән, яңа гыйлемне кабул итәрлек дәрәҗәдә әзерлекле булырга тиеш. Яңа савылган сөтне иске турсыкка салырга ярамаган кебек, яңа гыйлемне дә искергән карашлар, уйдырмалар һәм саташулар белән тулып торган бер акылга кертү мөмкин түгел. Муса әфәнденең фикерләрен аңларлык һәм кабул итә алырлык дәрәҗәдә уяу, зирәк, сизгер һәм акыллы, рухлары нык, иманнары пакь вә вөҗданнары саф кешеләр аның замандашлары арасында бик аз булган. Калган мөселман гаммәсе тирән йокыда калуын дәвам иткән. Шуңа күрә мирасына тиешле бәя бирү, аның әһәмияте вә кадерен

аңлау, һәм иң мөһиме – аны гамәлгә кертү, дини практикага әйләндерү безнең көннәрдә дә авырлык белән бара.

Муса әфәнденең исламияткә кагылышлы гыйльми хезмәтләренең саны дистәләгән. Аның әсәрләре Русиядә дә, чит илләрдә дә нәшер ителеп, дөнья буйлап таралган. Компьютерлар, информацион технологияләр, интернет мөмкинлекләре белән файдаланучы бүгенге кеше кимәле белән үлчәсәң, гади каләм-карандаш белән кәгазьдә язган бу галимебезнең акылга сыймаслык дәрәҗәдә зур, күләмле вә тирән мәгънәле дини, гыйльми, фәлсәфи, әдәби мирас калдырган булуын аңлыйсың. Боларның барысын да галим үзенең эш бүлмәсендә утырган көе генә эшләмәгән. Ул гомере буе бертуктаусыз җир йөзен гизеп торган. Алмания, Финляндия, Румыния, Ләхистан (Польша), Япония һәм Көньяк-Көнчыгыш Азиядәге колонияләр (хәзерге вакытта Малайзия), Госманлы дәүләтенең Хиҗаз (хәзер Согуд Гарәбстанының биләмәсе), Филистыйн (хәзерге вакытта Израил), Ливан һәм Шәм Шәриф (Иордания белән Сүрия), Гыйрак, Анадолу (Төркиянең Азия өлеше), Мисыр кебек биләмәләрне, Иран, Әфганстан, Кытай, Британ Һиндестаны (хәзерге вакытта Индия һәм Пакьстан) кебек илләрне зыярәт иткән, анда үз күзләре белән күргән хәл-әхвәлләрне китап-мәкаләләрендә чагылдырган, куен дәфтәрләренә теркәп куйган.

Муса Җаруллаһ, әйтерсең, «җанлы университет» булган һәм, әгәр бүгенге көндә эшләнсә, йөзләгән белгечләрнең киеренке хезмәтен таләп итәчәк гамәлләрне ул берүзе башкарып чыккан. Аның мирасы гаять күпкырлы. Галим ислами фикер тарихы вә фәлсәфә белән шөгыльләнгән, исламияткә мәхәббәт уяту гына түгел, аны тирәнтен аңлап башкаларга да җиткерү юлларын салган, динебезнең үткәнен җентекләп өйрәнеп, аның киләчәктәге язмышын уңай якка үзгәртүне кайгырткан. Аның әсәрләре халыкка рухи-интеллектуаль яңарыш юлларын, борынгылыкка тарткан тәкълиднең үтергеч богауларыннан, акыл тоткынлыгыннан котылу мөмкинлекләрен күрсәткән. Үзенең хезмәтләрендә галим хак иман вә тугры гамәл, фикер иреге, калеб сафлыгы, ихсан вә ихлас кебек төшенчәләрнең асылын

ачып, мәгариф, тәрбия һәм әхлак мәсьәләләрен хәл итү ысуллары, ислам дөньясын торгынлыктан, бөлгенлектән коткару турында сүз йөрткән. Муса әфәнде бәян иткән идеяләрнең кайберләре тышкы мөселман дөньясында яшәүче замандашларыбыздан булган дин галимнәре тарафыннан әле генә телгә алына башлап, зур яңалык, мөһим ачышлар буларак кабул ителәләр. Әгәр Муса әфәнденең туган телендә язган китапларын укыган булсалар, «менә нинди фикергә килдем, тыңлагыз!» дип сөрән салырга, әлбәттә, базмаслар иде.

Муса әфәнде язган әсәрләрнең, әйтеп калдырган фикерләренең, төшенчәләренең һәм идеяләренең, алымнарының, методларының, чараларының йогынтысы көннән-көн көчәя генә барачак. Аның рухи-интеллектуаль мирасындагы динне аңлауны, тормышны, дөньяга карашны дөресли алачак кайбер җәүһәрләрен генә атап узам: илаһи мәрхәмәтнең һәрнәрсәне үз эченә алган гомумилеге турындагы тәгълимат, җәһәннәм җәзасының мәңгелек булмавы турындагы тәгълимат, озын көннәрдә ураза һәм намаз мәсьәләсен хәл итү, усул-ы фикъһы гыйлемен яңарту, исламда хатын-кызның урыны, әһәмияте һәм ислам дөньясының тәрәккыяте өчен хатын-кыз мәсьәләсен хәл итүнең алшарт булуы, мөселманнарның фикерләүләрен мөстәкыйльлеккә һәм бәйсезлеккә ирештерү мәсьәләләре, азык-төлектә хәлал вә хәрам мәсьәләләре, Коръән кәримдә нәсехнең, ягъни бер айәт белән башка бер айәтне гамәлдән чыгаруның юклыгы, исерткеч эчемлекләрнең һәм матдәләрнең хәрамлыгын раслау, борынгы фәкыйһлар мирасын изгеләштереп, аңа сукырларча тәкълид кылуның, ягъни ияреп кабатлауның һәлакәткә китергән яман нәтиҗәләре, шигый мәзһәбенең карашларын Коръән, сөннәт вә тәүхид күзлегеннән тәнкыйть, Коръән айәтләрен һәм, гомумән, аның рухын дөрес аңлау һәм андагы хөкемнәрне һәм хикмәтне тормышта куллану үрнәкләре, мөселман дөньясының Көнбатыш колына әйләнүенең сәбәпләре, ирекле иҗтиһадның әһәмияте һәм кирәклеге, ислам мәгарифен үзгәртеп кору, дөнья мәйданында башка мәгариф системалары белән нәтиҗәлелектә, алдынгылыкта ярышырлык хәлгә китерү мәсьәләләре, бөтендөнья мөселман

берлеген булдыру, ислам диненең матур киләчәге, Ахыр заман, имам Мәһди, Гайсәнең иңүе һәм бик күп башка актуаль һәм әһәмиятле дини һәм иҗтимагый мәсьәләләр.

Әлбәттә, боларның һәммәсе турында аерым-аерым мәкаләләр, хәтта китаплар язып чыгарга була һәм, бәлки, иншаллаһ, язылыр да. Ә хәзер игътибар үзәгенә яңадан галимнең тормыш юлын алыйк та, укучыларыбызны шул турыда кулыбыздан килгән кадәр мәгълүматлы итик.

Бу китапта төп игътибар Муса әфәнденең тәрҗемәи хәлен, ягъни биографиясен бәян итүгә юнәлтелде. Аның өммәт өчен һәм милләт өчен кылган хезмәтләре, язган китаплары, аларда кузгатылган темалар турындагы сүзебез шул үзәк тема белән үрелеп барды.

Аның тормыш юлы вакыйгаларга шул кадәр бай булган ки – күргән-кичергәннәре берничә кеше гомеренә җитәрлек. Муса әфәнде кадәр эшләгән, аның кадәр гыйлем туплаган, аның кадәр китаплар язган, аның кадәр сәяхәтләр кылган, аның күргәне кадәрне күргән башка бер кеше, шөбһәсез, татар милләтендә юк. Андыйлар башка милләтләрдә дә берән-сәрән генә очрый торганнардан булып, кешелек дөньясының безгә мәгълүм булган 5–6 мең еллык тарихында Муса әфәнде белән янәшә куелырлык шәхесләрнең саны ике кулдагы бармаклар санынннан артмас, мөгаен. Татар милләтен генә алыйк: чыннан да, берәүләр атаклы дин галимнәре булып, матур чапан киеп, гомерләрен мәчет-мәдрәсә белән үзенең эш бүлмәсе арасында үткәргәннәр; берәүләр җәмгыять хакына, милли мәдәният өчен бик күп хезмәт итеп, өстәвенә дөньяны да байтак гизгән булсалар да, дин өлкәсендә, дини фикер мохитендә эз калдырмаганнар; башка берәүләр сәфәрләрен китап итеп язып бастырсалар да, үзләренә тиңдәшсез бер һәйкәл куярлар иде, әмма иҗтимагый тормышта, милләт тормышында алар сизелерлек эш эшләмәгәннәр, дин турында әйтеп тә торасы юк; берәүләр сәясәт дөньясының иң югары нокталарына ирешсәләр дә, башка өлкәләрдә үзләрен күрсәтмәгәннәр. Муса әфәнденең тормышында гына киеренке дини, гыйльми, иҗтимагый, әдәби, сәяси, фәнни хезмәт белән бергә акылга сыймаслык күп ва-

кыйгалар, маҗаралар, фаҗигаләр, кайгы-хәсрәтләр, югалтулар янәшә киләләр. Муса әфәнде Бигиев – һәркемне чын мәгънәдә хәйран калдырырлык, сокландырырлык язмыш иясе булган. Аның язмышы аркылы татар цивилизациясенең никадәр югары үсешкә ирешкән булуын аңлауга таба юллар ачыла.

Моннан алда әйтелгәннәрдән аңлашылганча, тыйнак табигатьле, итәгать вә тәртипнең ни икәнен яхшы белгән, мал-мөлкәт, көмеш-алтыннар артыннан кумаган Муса әфәнде – бөтендөнья ислам дини фикеренә һәм фәлсәфәсенә бик зур тәэсир ясаган санаулы галимнәрнең берсе, тиңдәшсез фикер иясе булып тора. Русия мөселманнары гына түгел, дөньяның төрле кыйтгаларында яшәүче мөселман кардәшләре дә мөхтәрәм галимне тиешенчә кадерли, олылый белгәннәр. Хикәяләүнең хронологик тәртибеннән чыгып, киләчәк вакыйгаларга күз ату исәбенә булса да, Муса Җаруллаһның никадәр абруйлы могътәбәр бер галим булуын таныта торган күпсанлы мисаллардан өчесен биредә дә искәртеп узарга кирәк: 1930 елда Муса әфәнде Советлар Берлегеннән качып китәргә мәҗбүр була. Юлы Әфганстан аша узганда, аны бу илнең падишаһы Мөхәммәт Надир-Шаһ кунак итә, шөһрәтле галимне Кабулда калырга, дәүләт исәбенә хосусан аның өчен мәдрәсә ачып җибәрүне вәгъдә биреп, шунда җитәкчелек итәргә һәм укытырга тәкъдим ясый. Икенче мисал Муса әфәнденең 1939 елда Һиндестанда Бөек Британия колониаль идарәсе тарафыннан кулга алынуы белән бәйле. Колониаль идарә зинданыннан шөһрәтле дин галимен Бһопал вилаятенең губернаторы Мөхәммәт Хәмидулла-Хан йолып ала һәм Икенче бөтендөнья сугышы беткәнче иркле хәрәкәт итү хокукыннан мәхрүм Муса әфәндене үзенең сараенда мәртәбәле кунак итеп тора. Муса әфәнденең Каһирәдә үткән соңгы көннәрендә аны багып торучыларның берсе, соңыннан Мисыр хидивләре (хөкемдарлары) каберлегендә урын хәстәрләп мәрхүмне шунда дәфен кылдыручы Мисыр хидивләре нәселенең вәкиләсе принсес Фәхренниса Хәдичә Хильми Габбас ханым була.

Муса әфәнденең мәшһүр шәхес, олы ихтирам казанган галим булуын раслый торган мисаллар байтак. Әле китерелгән өч мисалны мин, гадәттә, Муса әфәнде турында лекция-фәлән кебек чаралар үткәргәндә тыңлаучыларыма ишеттергән беренче сафтагы мәгълүмат рәвешендә китерәм. Болай итүемнең сәбәпләре дә бар. Ул сәбәпләрнең берсе үткән заманга карый: Муса әфәнде үзе исән чакта ук аның ислам диненең мәгънәсенә, эчтәлегенә, киләчәгенә карата булган карашлары күпләргә юл күрсәткән, исламның матур киләчәгенә өметләндергән һәм инандырган. Әмма, асылда танырга мәҗбүрбез ки, хакыйкать белән борынгылыкны бер үк нәрсә итеп күрү аркасында шуңа ябышып яткан замандашларының күпчелеге аның фикерләрен аңлый алмаган. Болай дигәндә сүз, әлбәттә, Муса әфәнденең әсәрләрен укып, галимнең алга сөргән идеяләре белән таныш булган кешеләр турында гына түгел, кара гайбәт, имеш-мимешләр корбаны булганнар турында да бара. Икенче сәбәп минем үз тәҗрибәмә бәйле – моннан күп еллар элек дин әһелләребезнең берсе, Муса әфәнденең гыйльми мирасын игътибарга лаек булмаган бер нәрсә итеп күрсәтер өчен, миңа: «Муса Бигиев ул әлләкем түгел – нибары гади бер журналист!» – дигән иде. Һәм алга таба да ул кешенең Муса әфәнде турында төрле нахак сүзләр таратып, аның исеменә тап төшерергә тырышып йөргәнен беләм. Андыйлар хәзерге көндә дә юк түгел, чөнки Муса әфәнденең исеме танылга, аның әсәрләре, фикерләре халык арасында тарала барган саен, аларга карата уңай яки тискәре мөнәсәбәттә булучыларның саны да арта. Олуг галимнең фикри мирасы белән танышканнан соң, битараф булып калу, чыннан да, кыен.

Бүгенге көндә Муса әфәнденең дини иҗтиһадына тиешле югары бәя бирелә башлады. Мәсәлән, галимнең илаһи мәрхәмәтнең гомумилеге турындагы тәгълиматы хәзерге Русиянең мөселман дин әһелләре, аерым алганда Россия Федерациясенең Үзәк Диния нәзарәте җитәкчелеге тарафыннан исламның алга таба үсешен һәм мөселманнарның рухи халәтен дөрес юнәлештә тәрәккый иттерүне тәэмин итәрлек идеологик мәсләк буларак кабул ителде. Бу мөфти шәех Ра-

вил Гайнетдиннең 2016 елның 19 февралендә Казан федераль университетында укыган лекциясендә әйткән сүзләреннән ачык күренә[1]. Шул ук дини оешманың канаты астында инде күптән «Муса Бигиев укулары» исемле еллык халыкара гыйльми-теологик конференция эшләп килә. 2021 һәм 2022 еллардан башлап, әлеге конференция Санкт-Петербург университетының Шәрык телләре факультеты базасында үткәрелә башлады. Мәскәү Ислам институтында Муса Бигиев исемендәге Тикшеренү үзәге ачылды.

Муса әфәнденең мирасын өйрәнү дәвам итә. Иң кызу темп белән бу эш Төркиядә бара. Бу илдә аңа багышланып язылган диссертацияләрнең, китапларның һәм фәнни-популяр эшләрнең саннары йөзләгән. Русиядә дә хәрәкәт күренә: галимнең берникадәр хезмәтләре инде рус теленә тәрҗемә ителеп басылып чыкты, татар теленә дә тәрҗемә итүнең күләме арта бара. Бу юнәлештә эшләнгән эшләр китабыбызда Муса әфәнденең әсәрләреннән өзекләр китерүне мөмкин итте. Ул өзекләрнең кайберләре галимнең тәрҗемәи хәле белән бергә бирелде, кайберләре III бүлектә урын ала.

Муса әфәнде хезмәтләреннән, язмаларыннан, хатларыннан китерелгән парчалардан аның нинди телдә язган булуын да аңларга мөмкин булачак: кайбер мисаллар элеккеге язудан хәрефләтә күчермә булып, андагы һәр аңлашылмаган сүз астөшермәдә китерелә; кайбер үрнәкләр хәзерге татар теленә берникадәр яраклаштырылган рәвештә бирелә, ягъни асыл текст билгеле бер «тирәнлектә» тәрҗемә ителеп, андагы мөһим төшенчәләр һәм дини-фәлсәфи терминнар үзгәртелмичә китерелделәр, чөнки болай итүебез тел байлыгын да, интеллектуаль багажны да арттырырга ярдәм итәчәк; кайбер парчалар мөмкин кадәр «тирәнгә төшеп» тәрҗемә ителделәр – боларны укыганда Муса әфәнденең теле белән хәзерге заман татар теле арасында нинди тирән упкын ятканы күренәчәк; һәм, ниһаять, кайбер документлар рус телендә бирелде – алар йә баштан ук рус телендә язылган, яки соңгы еллар дәвамын-

[1] Кара: URL: http://moskva.bezformata.ru/listnews/muftij-shejh-ravil-gajnutdin/43853189/

да шул телгә тәрҗемә ителгән. Гомумән алганда, тәрҗемәләр нинди генә ысул белән эшләнсә дә, максатыбыз – укучыларга галим мирасы белән аз гына булса да танышу мөмкинлеген бирү.

Бу китапта Муса әфәнде Бигиевнең тормыш юлын һәм мирасын инде менә 28 ел дәвамында өйрәнүнең нәтиҗәләре урын ала. Биредә китерелгән байтак кына документлар татар мохитендә, кайберләре, гомумән, фән дөньясында әлегә кадәр һичкайда да басылмаган, кайберләренең, хәтта, барлыгы да мәгълүм түгел иде. Бу яктан китабыбызда бәян ителгән мәгълүмат, һичшиксез, фәнни әһәмияткә дә ия.

*Айдар Хәйретдинов,*
*Казан,*
*2022, июль*

# I бүлек.
# Муса Җаруллаһның тәрҗемәи хәле, эшчәнлеге һәм әсәрләре

# Беренче фасыл:
# Муса әфәнденең гаиләсе, фамилиясе; балачагы һәм яшьлеге

Муса Җарулллаһның атасы Габделкәрим углы Ярулла әфәнде борынгыдан килгән Дәүликәм-угыллары нәселенең вәкиле булып, Русия империясенең Пенза губернасы Чембәр өязенә кергән Алтавыл исемле татар авыллары төркеменең Кикин авылында туган, шул авыл мәдрәсәсендә дини гыйлем алган. Дин белеме дигәндә, Ярулла әфәнде аны булачак каенатасы Биктимер углы Хәбибулла хәзрәтнең кулы астында үзләштергән.

Сүз уңаеннан, әлеге Алтавыл исемле географик атаманың этимологиясенә, ягъни тамырларына да игътибар итәргә кирәк. Бу сүз XVI йөзьеллыкның ахырларына кадәр Хивә белән Кырым арасындагы далаларда күчмә тормыш белән яшәгән Алтыугыл исемле нугай ыруының исеменә барып тоташа. Бу хакта үзенең хатирәләрендә Муса әфәндене шәхсән белгән замандашы һәм танышы Әхмәт-Зәки Вәлиди[1] язган. Муса әфәнде 1932 елда Төркиягә килгәч, алар икәүләп XX гасырның иң зур сугыш мәйданы булган Чанак-кальга шәһәрен зиярәт итәләр. «Tasvir» гәзитендә чыккан мәкаләсендә Тоган болай дип яза: «*1926 елында Төркиягә килгәнендә бәрабәр Чанаккале, Анафарта, Сәдделбәхер тарафларын гиздек. Өйрәнгәнемә күрә, үзе борынгы нугайларның Алтавыл (Алты угыл) ыруының көньяк Русиядә җирләшеп калган һәм*

[1] Әхмәт-Зәки Вәлиди (Әхмәтшаһ углы Әхмәт-Зәки Вәлиди Тоган; 1890–1970) – күренекле сәясәт эшлеклесе, 1917–1920 елларда башкорт азатлык хәрәкәтенең юлбашчысы, Бәйсез Башкортстан хөкүмәтендә хәрби департамент башлыгы; публицист; тарихчы, шәркыятьче галим, фәлсәфә докторы (1935), профессор, Манчестер университетының шәрәфле докторы (1967); Муса Бигиевтән шәхси сабак алган шәкерт; күпсанлы фәнни китаплар авторы.

*бүген мишәр төркләреннән саналган бер нәселдән чыккан ки, әле 16нчы гасырда бер өлеше Харәземдә җирләшкән, башка өлеше Азак, Кырым вә Әстерхан арасында җәйләп йөргән бер нәселдер»*[1].

Җирле халык авызыннан язып алынган икенче хәбәргә күрә, Әби патша гаскәрендә хезмәтен тәмам итеп башкаладан китәргә җыенган Арыслан Полкаев исемле бер татардан Әби патша: «Хезмәтең өчен нәрсә бүләк итим сиңа?» – дип сораган, имеш. Арыслан: «Бүләк кирәкми, мин җир яратам, миңа җир бир!» – дигән. Падишаһ хатын: «Бер көн дәвамында атыңа атланып никадәр җирне әйләнеп чыксаң – шул кадәр җирне сиңа яздырырмын», дип вәгъдә иткән, имеш. Арыслан юргасына атланган да чаптырган: Титаудан Аргамакка кадәр, Аргамактан Кече Чембәргә таба. Шул өч нокта арасында Рәшәтә, Мочаләй, Кубылкай, Теләтей, Кутай исемле алты татар авылына нигез салынган, имеш. Әлбәттә, бу соңгысы – имеш-мимешкә корылган җирле легенда гына. Муса әфәнденең Тоганга сөйләгән нәсел тарихы исә хакыйкать бизмәнендә ул легендалардан күпкә авыррак күренә.

Идел буендагы Пенза губернасында гомер иткән Дәүликәм-угыллары токымы берничә гасыр дәвамында шунда яшәп, иген игеп, мал-туар асрап көн күргән. XIX гасырның 70 елларында Габделкәрим углы Ярулла әфәнде туган авылын калдырып, кайбер хәбәрләргә күрә, Дон елгасы ярында урнашкан Ростов-на-Дону шәһәренә барып җитәсе Мәскәү – Ростов-на-Дону тимер юлы төзелешенә мөтәгаһһид[2] буларак кушыла һәм хәләл җефете Хәбибулла кызы Фатыйма ханым белән 1870 елда туган углы Мөхәммәд-Заһирны һәм аннан

[1] Prof. Zeki Velidi. Musa Carullah, mesleği, şahsiyeti ve eserleri. Tasvir. (бу мәкаләнең кулымдагы электрон нөсхәсендә Tasvir газитенең чыккан датасы күренми. Әмма аның 1946 елда язылган булуы, бер яктан, автор китергән мәгълүмат белән дә (1875+71=1946), икенче яктан, Муса әфәнде биографиясенең фактлары белән дә раслана).

[2] мөтәгаһһид – ялланып эшләүче; подрядчик.

алда туган 24 баласын ияртеп яңа җирләргә, яңа тормышка таба юл тота.

«24 баласын ияртеп» дигән гыйбарә никадәр шаккатыргыч булса да, Ярулла хәзрәт әфәнденең Мөхәммәт Заһир белән бергә 25 баласы булуы турында Муса Бигиев үзе язып калдырганны да әйтеп узарга кирәк[1].

Муса әфәнденең үзе дигәндә, ул әлеге ишле гаилә яңа урынга күченгән чакта юлда, ат арбасында дөньяга килә дигән сүз бар. 1914 елда Фатих Әмирханга[2] язган бер хатында Муса әфәнде туган урыны турында да сүз әйтеп, ата-анасы Пенза губернасыннан Ростов-на-Донуга күченгән чакта Новочеркасск шәһәре янында юлда туганын белдергән. Байтак еллар үткәч үз кулы белән тутырган бер анкетада ул туган урыны итеп Пенза губернасының Чембәр каласын күрсәтә[3]. Чынлыкта, Мусаның ни туган елы, ни туган урыны тәгаен генә билгеле түгел, шуңа күрә бу мәсьәләгә алга таба аерым туктап алырбыз.

Муса әфәнденең дөньяга килүе юлда, ат арбасында булуы, аны көткән тәкъдирнең бер ачык ишарәсе буларак кабул ителә ала, чөнки аның бөтен тормышы еракларга сузылган юлларда, чит-ят илләргә илткән сәфәрләрдә, туктаусыз хәрәкәттә уза.

Әмма без Ярулла хәзрәткә әйләнеп кайтыйк. Тимер юл төзелешенә эшкә яллану аны гаиләсе белән бергә Русиянең күктә мул кояшлы, җирдә бәрәкәтле туфраклы тарафларында урнашкан Ростов-на-Дону каласына алып килә. Ул заманда кайнап торган күп милләтле, бик эшлекле һәм зур сәүдә үзәге булган бу шәһәр Ярулла әфәнденең күңелен яулаган, күрәсең: кичә генә авыл агае булган Ярулла хәзрәт яңа урында ни-

[1] Муса Бигиев. Мөхәммәт Заһир әфәнде Бигиев. Мөхәммәт Заһир Бигиев. Мәвараэннәһердә сәйахәт. Трансоксанияйә сәфәр. Казан: «Китап» нәшр., 1908. Б. 2.

[2] Фатих Әмирхан (Зариф углы Фатих Әмирхан; 1886–1926) – күренекле татар язучысы, яңа заман татар классик әдәбиятына нигез салучыларның берсе, публицист, тәрҗемәче. Муса әфәнденең дусты.

[3] Тагирджанова А. Н. Книга о Мусе-эфенди, его времени и современниках. Казань, 2010. С. 165.

гезләнеп, шәһәрчә гомер итә башлаган. Табигате белән җитез, хәрәкәтчән, кул эшләренә оста Ярулла әфәнде яңа урында тиз арада үзен тапкан, җирле шартларга яраклашып, яңа эшен уңышлы гына башкарып, азмы-күпме акча туплый алган һәм ул капиталны, татарга хас бер мәйелгә ияреп, алыш-биреш вә сәүдә юнәлешендә арттырып, гаиләсенә җитешле тормыш корып җибәргән, азмы-күпме күчемсез мал-мөлкәт иясе булып киткән. Өстәвенә Ярулла әфәнде, җитәрлек кадәр дини белемгә ия булуы сәбәпле, гомеренең соңгы елларында Ростов-на-Донуда яшәгән татар әһалисенә һәм башка мөселман кавем-кабиләләренә ахунд мулла буларак дини вә рухи хезмәт күрсәтеп яшәгән.

Ярулла әфәнденең ахундлык һәм муллалыгына кагылышлы бер риваять тә сакланган: имештер Оренбург Диния нәзарәте мөфтие Сәлим-Гәрәй Тәфкилев[1] (1805–1885) хаҗга барышлый Ростов-на-Дону шәһәре аша узганда Ярулла әфәнде өендә кунак ителгән. Ул чакларда нибары 161 кешедән гыйбарәт җирле татар җәмәгатьчелегенең дини хаҗәтләре шәригатьчә тиешле сурәттә үтәлә алсын өчен, мөфти хәзрәтләре Ярулла әфәндене җирле мәхәлләнең ахуны итеп билгеләгән, имеш. Кызыклы кыйсса, тик Сәлим-Гәрәй мөфтинең хаҗны 1852 елда кыйлган булуын истә тотканда, Ростов-на-Донуга 1870 елларның башында гына барып урнашкан Ярулла әфәндене ахун итеп карар кыйлган булуы шик тудыра. Әмма Муса Бигиевнең хәбәренә күрә, Ярулла хәзрәт ахундлыкка, чыннан да, Сәлим-Гәрәй мөфтинең карары белән куелган булып чыга[2]. Ни генә булса да, 1881 елда Ярулла әфәнде дөнья мәшәкатьләрен калдырып Аллаһ хозурына күчә. Шәфкать иясе булган Раббымыз аның рух шәрифләрен шат кыйлсын!

---

[1] Сәлим-Гәрәй Тәфкилев (Шаһингәрәй углы Сәлимгәрәй Тәфкилев; 1805–1885) – Тәфкилев морзалар нәселенең вәкиле, 1865–1885 елларда Оренбург Диния нәзарәте мөфтие.

[2] Муса Бигиев. Мөхәммәт Заһир әфәнде Бигиев. Мөхәммәт Заһир Бигиев. Мәвараэннәһердә сәйахәт. Трансоксанияйә сәфәр. Казан: «Китап» нәшрияты, 1908. Б. 2.

Ярулла әфәнденең тырышлыгы, тапкырлыгы һәм диндар бер зат булуы угылларына да үрнәк булган, аның балаларына биреп өлгергән ата тәрбиясе дә тәэсир итми калмаган булса кирәк.

Мөхәммәд-Заһир белән Мусаны багу, кайгырту һәм тәрбия кыйлу тулаем тол калган аналарының җилкәсенә ята. Фатыйма ханым бу вазифасын җанын фида кыйлу бәрабәренә башкарып чыга: иң элек балаларына башлангыч дини гыйлем бирә. Бу җәһәттән аны абыстай ханым дип тә атап була. Моннан тыш, Мусаның дөньяви уку йортында – Ростов-на-Дону шәһәренең «Петровское реальное училище»да[1] белем алуын тәэмин итә. Димәк, Фатыйма ханым өчен заманча фикер йөртү дә ят нәрсә булмаган.

Биредә Муса әфәнденең шәхсияте, фикерләве һәм дөньяга карашының нинди мохиттә шәкелләнгәненә дә игътибар итәргә кирәк. Киләчәктә олы дин галиме булып җитешәчәк бала, бер яктан, традицион татар гаиләсендә туып-үсеп тәрбияләнгән. Икенче яктан, аның консерватив һәм бермилләтле татар авылында түгел, Русиянең этник һәм дини җәһәтләрдән иң чуар шәһәрләренең берсе – Ростов-на-Донуда үсүен дә истә тотарга кирәк. Җирдәге һәм судагы сәүдә юллары чатында урнашкан әлеге шәһәр XIX йөзнең ахырында Көньяк

---

[1] Муса әфәнденең Ростов-на-Донуда кайсы дөньяви уку йортында укуы әлегә кадәр тәгаен генә билгеле түгел иде. Әмма бу китап язылганда Бигиев мирасының хокукый җәһәтләрен өйрәнүче галим Динар Зәйнетдиновның «Муса Бигиев: в зените исламского права» исемле зур хезмәтенең кульязмасы кулыма керде. Ростов өлкәсе дәүләт архивында саклана торган документларга нигезләнеп, Зәйнетдинов әлеге сорауга ышанычлы төгәл җавап бирә: «Поэтому из небольшого числа учебных заведений Ростова-на-Дону, даты их основания и направленности (религиозные или светские, мужские или женские), можно предположить, что Муса Бигиев учился в «Ростовском-на-Дону Петровском реальном училище» (даты существования – 1873–1919 годы). Реальные училища представляли собой среднее или неполное среднее учебное заведение, в котором существенная роль отводится предметам естественной и математической направленности» (кульязманың 33 бите).

Русиянең мөһим мәдәни һәм рухи үзәгенә әйләнгән. Шуңа ул үзенә тәвәккәл һәм булдыклы кешеләрне күпләп җәлеп иткән. Аның су лиманнары өчен грек, итальян, төрек, әрмән, фарсы сәүдәгәрләренең кораблары ят күренеш булмаган. Шәһәр бик тиз темплар белән үскән, аның әһалисенең саны туктаусыз ишәя килгән, сәнәгать предприятиеләре һәм остаханәләр саны артканнан арта торган. Мәсәлән, 1860 елда шәһәрдә нибары 17574 кеше яшәгән булса, инде 1893 елда бу сан 100 меңгә җиткән, ә 1897 елда Русиядә үткәрелгән беренче Халык саны алу мәгълүматларына караганда, Ростов-на-Донуда 119 476 кеше, һәм шуның өстенә 2500 чит ил кешесе яшәгән.

Муса Бигиев гомеренең беренче елларын әнә шундый гөрләп торган шәһәрдә үткәргән һәм дөнья белән таныша башлаган. Шунысын да билгеләп үтәргә кирәк ки, яшьтәшләренең абсолют күпчелегеннән аермалы буларак, Муса Бигиевнең рус телендә дә белем алуы аның шәхсиятенә дә, зиһененә дә, дөньяга карашларына да, әлбәттә, тәэсир итми кала алмаган.

Угылларының киләчәкләренә бәйле хыялын тормышка ашырыр өчен, Фатыйма ханым 1887 елда Мөхәммәд-Заһирны һәм бераз соңрак Мусаны Казандагы «Күл буе» яки, башка исеме белән, «Касыймия» мәдрәсәсенә[1] укырга җибәрә.

Мөхәммәт-Заһир биш ел кадәр вакыт мәдрәсәдә укып, 1891 елда туган шәһәренә кайта һәм имам булып эшли башлый. Әмма моның белән бергә ул татар әдәбияты тарихында да тирән эз калдыра – Заһир Бигиев татар реалистик прозасына нигез салучы булып санала. Тәкъдир галиҗәнапләре Мөхәммәд-Заһир бичарага озын гомер яшәргә насыйп итми – ул 1902 елда фаҗигале сурәттә вафат була. Мәрхәмәтенең чиге булмаган Аллаһ тәгалә хәзрәтләре яшьли китеп барган Мөхәммәт-Заһир әфәнденең рух шәрифләрен шат кыйлсын!

Мусаның гомере исә озын, вакыйгаларга бай һәм хәсрәтле булып, шул ук вакытта эш вә хезмәт белән тулылыгы арка-

[1] «Касыймия» мәдрәсәсе – Казанда Апанай мәчете каршында 1770 елда ачылган мәдрәсә. Уку-укыту рәвеше Бохара калыпларына туры китерелгән була. XX гасыр башында укыту программасы үзгәртелеп, дөньяви фәннәр дә укытыла башлый.

сында, гаять мәгънәле һәм бәрәкәтле була. Бу турыда сүзебез алда әле. Тик хикәяләвемне дәвам иткәнче, минем кабат Фатыйма ханымга әйләнеп кайтасым килә.

Ни генә булса да, ана буларак Фатыйма ханым күңел түрендә асраган максатын тормышка ашыру бәхетенә ирешә, чөнки ике углының да дин галимнәре булып җитешүләрен күреп өлгерә. Шулай итеп, ике баласын аякка бастырганнан соң, 1908 елда Фатыйма ханым бу дөньядан бакыйлыкка күчә. Мәрхәмәтле Аллаһ тәгаләбез аның рух шәрифләрен шат кыйлсын!

Фидакяр ананың балалары хакына кылган барлык эш-хәрәкәтләре, сарыф иткән һәммә матди чыгымнары – аларны укымышлы, зыялы, диндар, гыйлемле һәм Россия шартларында аякларында нык тора алырлык кешеләр итеп күрү теләгенең чагылышыдыр. Матди чыгымнар дигәннән, тагын бер-ике сүз әйтелергә тиеш: Фатыйма ханымның балаларын Казанга кадәр юллап мәдрәсәдә, Мусаны реальный училищеда укытуы, аннары аның чит илләргә китеп, 1904 елга кадәр дәвам иткән белем алу һәм гыйлем туплау сәфәрен акчалата тәэмин итеп торуы – болар барысы да хәлал вә сум акча таләп итә торган эшләр. Шуңа күрә күренекле татар язучысы, әдәбият классигы Мөхәммәт-Заһир булсын, бөтен ислам дөньясында дан вә ихтирам казанган арбуйлы дин галиме Муса булсын – әлеге ике шәхеснең татар цивилизациясенең күгендә якты йолдызлар булып балкып торулары һәммәсе дә – рухи көчләрен, җан җылысын, бәдән куәтен вә мал-мөлкәтен үз-үзен аямыйча балаларына багышлаган ана галиҗәнаплә-ре Фатыйма ханымның бәрәкәтле хезмәте нәтиҗәсе вә җимешләредер.

Фатыйма ханымның балалары өчен никадәр могътәбәр һәм газиз кеше булуын аңлар өчен, Мөхәммәт-Заһир белән Мусаның Дәүликамов фамилиясен түгел, Бигиев фамилиясен алуларына игътибар итәргә кирәк. Бигиев фамилиясен сайлау ике ир баланың нәкъ менә аналарына карата саклаган олуг ихтирамнарының ачык ишарәсе булып тора. Бу эшнең башы Фатыйма ханымның бабасы булган Биктимер аганың

Бигиугыллары[1] токымыннан булуына барып тоташа. Димәк, Бигиев дигән фамилия Мөхәммәт-Заһирны да, Муса әфәндене дә аналары ягына сузылган нәсел тамырлары белән бәйли. Моннан тыш, туган иленнән, сөекле гаиләсеннән читтә, кырыс горбәтлектә яшәгән дәвердә Муса әфәнде, кадерле анасы Фатыйма ханыма ихтирамын белдерү йөзеннән, берничә әсәрен Ибне Фатыйма, ягъни Фатыйма углы дип имзалаган. Шулай үзен анасының исеме белән белдереп, ислам әдәбияты горефендә аңарчы һич очрамаган адым атлаган, аны дөньяга китереп аякка бастырган мөбарәк ханым-әфәнде – әнисе Фатыйма абыстайга кыяматкәчә сакланачак һәйкәл куйган.

Муса әфәндењ фамилиясе турында өстәп әйтеләсе тагын берничә сүз бар: Русиядә һәм Советлар берлегендә татар милләтенең бу олуг дин галиме һәм фикер иясе, күбрәк, Бигиев фамилиясе белән мәгълүм булган. Шул ук вакытта Русиядә басылган байтак кына әсәрләрен, аеруча Санкт-Петербургта һәм Петроградта нәшер ителгәннәрен, ул, тагын берничә автограф белән беррәттән, Муса Җаруллаһ дип тә имзалаган. Тышкы мөселман дөньясында исә аны, гомумән, Муса Җаруллаһ буларак кына беләләр. Әлеге сүз атасының исеменә барып тоташа, ягъни Яруллаһ углы Муса (Муса Яруллович). Ярулла сүзе чыгышы белән гарәп телендәге *җару Аллаһи* (جار الله), ягъни *Аллаһның якыны*, дигән гыйбарәгә бәйле. Димәк, Муса әфәнде татарлашкан Ярулла сүзен аның гарәпчә асылына кайтарып, Җаруллаһ иткән. Әлеге сүз мөселман колагына ишетелгәндә дә, язу буларак күзенә күренгәндә дә сораулар тудырмаган. Бигиев фамилиясе иясенең татарлыгына ишарә итеп, никадәр милли булса да, мөселман мохите, бигрәк тә Муса әфәндењ чит илләрдәге диндәшләре өчен, мондый фамилия сәер булып тоелыр иде, истә дә калмас иде.

[1] Әлеге фамилиянең башта Бики угыллары шәкелендә булуы тәгаен ачык күренә, әмма ике сузык аваз арасында калган саңгырау «к» тартык авазы яңгыраулашып «г»га әйләнә, шул рәвешле Бики угыллары Биги угыллары булып китә.

## Муса Җаруллаһ биографиясенең хронологик бүленеше

Муса әфәнденең тормыш юлы һәм аны өйрәнүне җиңеләйтү йөзеннән этапларга бүлү мәсьәләләрен кузгатыр алдыннан, аның туган һәм вафат булган елларына тукталып алыйк.

Муса Җаруллаһның 1871 ел белән 1875 еллар арасында дөньяга килгән булуы мәгълүм. Туган көне турында төгәлрәк мәгълүматны табуы кыен. 1923 елда үзеннән сорау алу протоколында ул туган елын 1871 ел дип күрсәткән. Муса әфәнденең миңа танышып-күрешеп өлгерергә насыйп булган кече кызы Фатыйма ханым Таһирҗанова үзенең хатирәләрендә этисенең туган көне датасын 1873 елның 25 декабре дип күрсәткән[1]. Кайбер ышанычлы чыганакларда бу дата 1874 елның 24 декабре дип билгеләнә. 1914 елда Фатих Әмирханга язган бер хатында Муса әфәнде кайсы елда дөньяга килгәнен төгәл белмәве турында ачыктан-ачык язган. Әлеге хатта ул туган көнен 1875 елның ноябрь-декабрь айлары дип атаган. Башкалар 1875 елның 24 декабрен[2] әйтәләр. Бу дата Әхмәт-Зәки Вәлидинең инде искә алынган мәкаләсендә күрсәтелгән датага туры килә. Анда Муса әфәнденең туу датасы турында Вәлиди: «*Үзе 24.12.1875 елында туганына күрә хәзер 71 яшендәдер*»[3], дип язган. Шулай ук аның туган вакытын 1875 елның ноябрь яки декабрь айларына бәйләгән чыганаклар да юк түгел. Башка берәүләр аның туган елын гына күрсәтеп, әлеге мәсьәләдә ае-көне кебек нечкәлекләргә кагылмыйлар. Мин әлеге датаны 1875 елның 24 декабре итеп күрсәтүне хакыйкатькә туры килә дип уйлыйм.

Муса Бигиевнең вафаты датасы төгәл мәгълүм – 1949 елгы октябрь аеның 25 нче көнендә галимнең рух шәрифләре әр-Рахман әр-Рәхим хозурына күчеп китә. Каһирәдә булган

[1] Тагирджанова А.Н. Күрс. хезм. Б.7.

[2] Taymas, A.– B. Musa Carullah Bigi, kisiliği, fikir hayati ve eserleri. İstanbul: M. Siralar Matbaasi, 1958. Б. 7.

[3] Prof. Zeki Velidi. Musa Carullah, mesleği, şahsiyeti ve eserleri. Tasvir.

бу моңсу вакыйга турында Мисыр һәм Төркия гәзит-журналлары мәрасим мәкаләләре бастырган булганнар.

Муса әфәнденең тормыш юлы күзгә күренеп торган өч өлешкә бүленә: 1) бала чагы һәм гыйлем туплау еллары. Утыз еллык бу чор, Мусаның дөньяга килгән көненнән башлап, 1904 елга кадәр дәвам итә; 2) икенче чор 1904 елдан 1930 елга кадәр сузыла һәм ул Муса әфәнденең ватанында – Россия империясендә һәм Советлар Берлегендә яшәгән егерме алты елын үз эченә ала; 3) өченче чор горбәтлектә, ягъни эмиграциядә яшәгән унтугыз елын колачлый. Бу дәвер, 1930 елдан башлап, шөһрәтле дин галименең 1949 елның октябрь аенда Аллаһ рәхмәтенә кавышып фани дөньядан бакыйлыкка күчкән көненә кадәр сузыла.

Муса әфәнденең тормышы турында алга таба хикәяләү югарыда билгеләнгән чорлар тәртибендә бәян ителер.

## Нурлы Казан вә Бохара-и Шәрифәдә

Муса әфәнденең балачагы һәм Казанда үткәргән шәкертлек еллары турында мәгълүмат бик аз. Һәрхәлдә, Фатыйма ханымның кече улына да сыйфатлы дини белем бирергә теләгән булуы көн кебек ачык. Бу унөч яшьлек Мусаны, реальный училищены тәмамлавын көтеп тормыйча, мәдрәсәдә укытыр өчен, 1888 елда Казанга – абыйсы Мөхәммәт-Заһир янына – юллавыннан күренеп тора. Ул чакта Мөхәммәт-Заһир Казанның иң борынгы – 1870 еллардан бирле эшләп торган дини уку йортларыннан булып, алдынгылыгы белән дан казанган «Күл буе» мәдрәсәсендә инде ике елдан артык вакыт дәвамында укыган була. Бу исәптән, энесе Мусаның да шул ук мәдрәсәнең шәкерте булып китүе – көтелгән хәл.

Төрле чыганакларга караганда, үсмер Муса Казан мәдрәсәсендә ике ел ярымнан[1] алып, дүрт ел ярымга кадәр вакытын үткәрә. Бу вакыт дәвамында аның мондый укудан тәмам гайрәте чигә һәм ул әнисеннән өйгә кайтырга рөхсәт бирүен үтенә. Фатыйма ханым Мусаны Казанда

[1] Тоган З. В. Musa Cârullah Begi’nin Hayatı ve Eserleri. С. 5.

көчләп тотмый. Шулай итеп, Казанда үткәргән шәкертлек дәвере 1889 елда тәмамлана да ул Ростов-на-Дону Реальный училищеда өзелеп торган укуын дәвам итә. Мусаның мәдрәсәдә укуын ташлавы, мөгаен, андагы тәртипләрне, уку-укыту рәвешен һәм, һәммәсеннән битәр – бирелгән белемнең сыйфатын хуш күрмәвенә кайтып кала. Муса әфәнде мөселман дөньясының төрле почмакларында урнашкан күпсанлы мәдрәсәләр, гомумән, дини мәгариф низамы, аның җитешсезлекләре, борынгыдан килгән чирләре белән бик якыннан, эчен-тышын айкап чыгып таныша һәм ахырда ифрат та күңелсез нәтиҗәләргә килә. Аның саф мөселман балаларының дини мәдрәсәләрдә укыганнан соң, аннан чып-чын кяферләр булып чыгулары турындагы дәгъвасе генә ни тора.

«Касыймия» мәдрәсәсендә уку тәҗрибәсе Мусаның мөселман мәгарифе белән танышу юлында атлаган беренче адымы булса, 1895 елда бу юнәлештә яңа бер адым ясала – әнисенең үгетләвенә күнеп, дини гыйлемен арттыру һәм тирәнәйтү максаты белән Муса әфәндебез Бохара-и Шәрифләргә, ягъни Изге Бохарага юл тота. Анасын, әлбәттә, яраткан һәм ихтирам иткән яшь егет, дөньяви белем алуын дәвам итәргә теләгән булса да, кадерле вәлидәсенең үтенечен кире кага алмаган. Моннан тыш, Бохараны чын ислами гыйлем учагы буларак кабул иткәнгә күрә, аның бу легендар, хәтта әкияти белем мәркәзендә алачак сабакка карата олы өметләр баглаган булуы да бик ихтимал.

Хатирәләренә караганда, бу борынгы белем үзәгендә Муса әфәнде биш ел гомерен үткәрә. Тик ни аяныч, Бохара мәдрәсәләрендәге уку-укытуның ни тәртибе, ни эчтәлеге өметләрен акламый. Монда күргәннәре аның Казанга бәйле шәкертлек хатирәләрендә сакланган истәлекләрдән дә яманрак күренгән булса кирәк. Мисал өчен, Бохарада XVI гасырдан бирле эшләп килгән данлыклы «Мир-и Гарәб» мәдрәсәсендә Муса әфәнде белән бер үк елларда диярлек дәрес алган, соңыннан танылган совет таҗик-үзбәк язучысы булып җи-

тешкән Садретдин Гайнинең[1] хатирәләреннән берничә парча китерәсем килә. Унтугыз ел дәвамында мәдрәсәләрдә дин белеме алганнан соң, тантаналы чыгарылыш көне турында Гайни хәзрәтләре болай дип язган: *«Ниһаять, мәдрәсәне тәмамлау көне җитә. Мөхәммәд пәйгамбәрнең хәдисен укыганнан соң остаз мулла, шәкертләренә мөрәҗәгать итеп, аларга үзе өйрәткән нәрсәләрне һәм аларга өйрәтмәгән нәрсәләрне башкаларга да өйрәтергә кушып хәер-фатихасын бирә. Аның шәкертләргә өйрәтмәгәннәре исә тәфсир, хәдис һәм башка дини гыйлемнәрне үз эченә ала»*[2].

Бохарада уку-укыту рәвеше һәм тәртибе, кулланылган дини әдәбият һәм дәреслек буларак хезмәт иткән әсәрләр XIII–XIV гасырлардан бирле һич үзгәрмәгән һәм үзгәртелмәгән хәлдә кала биргәннәр. Әлеге ышанычлы шаһитнең истәлекләренә күрә, Бохара мәдрәсәләрендә шәкертне чын мәгънәдә дин белгече, шәригатьче фәкыйһ, фикер йөртә белгән акыл иясе, мөселман җәмәгатьчелегенең рухын, әдәп-әхлагын һәм акылын тәрбия кылып камилләштерә алган абруй иясе дәрәҗәсенә күтәрергә тиешле гыйлемнәрнең берсе дә: ни Коръән гыйлеме, ни хәдис гыйлеме, ни фикъһы гыйлеме – өйрәтелмәгәннәр булып чыга. Гайни генә түгел, Муса әфәнде дә, аннан башка күренекле шәхесләр дә лаексыз рәвештә «дини белем учаклары» дип аталган мәдрәсәләр турында үзара бик охшаш хатирәләр калдырганнар.

Бу шаккатыргыч һәм аяныч хакыйкатькә инанырлыкмы? Юк, әлбәттә. Тик болай булганда, «Мәдрәсәләрдә нәрсә өйрәнгәннәр соң?» дигән сорауның тууы табигый. Бохарада йөз илледән артык мәдрәсә булып, аларда укыган шәкертләр санының утыз меңнән артык булуын истә тотканда, әлеге сорау тагын да

---

[1] Садретдин Гайни (Садретдин Сәет-Морадзадә; 1878–1954) – таҗик совет язучысы, җәмәгать эшлеклесе, галим, Урта Азия (Төркестан) халыклары тарихы һәм әдәбияты буенча фәнни хезмәтләр авторы. Таҗик совет әдәбиятына нигез салучы, үзбәк совет әдәбиятына нигез салучыларның берсе.

[2] Садриддин Айни. Бухара: (Воспоминания). В 2-х кн. Кн. 2 (Пер. с тадж. С. Бородина; Отв. ред и авт. послесловия К.С. Айни). Душанбе: Ирфон, 1981. кн. 1. С. 140.

кызыклырак яңгырый. Җавап бирү өчен кабат Гайни әфәнде язганнарга күз салыйк. Шәкертләрнең бер ел дәвамында мантыйкка багышланган «Шәмсия» китабына хәшия (аңлатма) буларак язылган «Хәшия-и Котби» исемле китапны өйрәнүләренең нидән гыйбарәт булуын күрсәтер өчен, ул мондый истәлекләр язып калдырган: *«Дәресләр бер генә сүз турындагы бәхәсләрдән гыйбарәт иде. «Шәмсия»нең авторы китапның башында гарәп телендә: «Бу китап бер мөкаддимәдән, өч мәкаләдән һәм бер йомгактан тора. Әмма андагы мәкаләләр өчтер»,– дип язган. Шулай итеп, китапның башында автор «өч» сүзен ике тапкыр язган. Моның бер ялгыш булуы аңлашыла, чөнки «өч» сүзен кабатлауның кирәге юк иде. Әмма бу турыда бер ел дәвамында гаугалы кызу бәхәс дәвам итте: әлеге башкатыргыч «өч» – ул артык сүзме, түгелме? Әгәр артык сүз булса, ул беренче гыйбарәдәме артык, әллә икенче гыйбарәдәме артык? Әлеге ифрат та әһәмиятле мәгънәгә ия булган мәсьәлә буенча бер ел буе бәхәсләшү соңында «Шәмсия»не язган кешенең – XIII гасырда яшәгән Нәҗметдин Гомәр Казвининың – бик мәгърифәтле берәү булганлыгы гына түгел, галим кеше булганлыгы турында да ачыш ясала иде дә, шуңа күрә аның мондый хатаны һич тә ясый алмавы хакында карар кыйлына иде. Ниһаять, әлеге хатаны иясенә белдермичә аның каләме ясаган булуы турында хөкемгә килделәр»*[1].

Югарыда китерелгән истәлекләр Муса әфәнденең Бохарада нинди хисләр кичергән булуы турында азмы-күпме фикер йөртер өчен азык бирә. Шулай да, аның әлеге борынгы данлыклы калада өч-дүрт ел вакытын үткәргән булуын да истә тотарга кирәк. Бу вакыт дәвамында ул нишләгән? Садретдин Гайни кебек ничарадан бичара хәлендә тынчу бүлмәләрдә бетмәс-төкәнмәс мәгънәсез бәхәсләрдә авыз суларын киптереп, колакларын шиңдереп утыргнмы? Юк, әлбәттә.

Чыннан да, Муса әфәнде гомер бакый тәвәккәл, җитез һәм тиктормас кеше булган. Әлеге табигате аны Бохарада үткәреләсе вакытыннан мөмкин кадәр күбрәк файда күрергә, гыйлем эстәү юлында тырышырга-тырмашырга этәргән. Шуңа

[1] Садриддин Айни. Күрс. кит. Б. 143.

күрә мәдрәсәләр никадәр шан-шәрәфле булсалар да, читтә торсын – тынгысыз Муса үзенә кирәкле сабакларны алганнан соң аларның диварларында тоткын булып утырырга теләми: ул җирле белем ияләрен барлап, аларның зиһеннәрендә сакланган гыйлем чишмәләреннән үзенә дә өлеш чыгарыр өчен абруйлы галимнәрнең ишекләренә таба сукмаклар салган. Бу турыда үзе болай дип яза: *«…нәрәйә холүл итмеш исәм дә, голүм диниясе монтазым мәктәб мәдрәсә йуклыгына күрә, ураның фәкыйһләре мөхәддисләре әдибләре хозурында хосусый сурәтдә ханәләренә кидүб, үз раэйемлә дәрес укур идем»*, ягъни, «кайда гына барсам да, дини гыйлемнәре тәртипкә салынган мәктәп яки мәдрәсә юклыгы аркасында, андагы шәригать белгечләренең, хәдисчеләрнең, әдипләрнең өйләренә барып, үзем теләгәнчә, хосусый дәресләр ала идем». Муса әфәнде язганча, ислам илләренең һәрберендә читтән килгән шәкертләрне кадерләп, зур ихтирам күрсәтеп хозурларына алып, түләүсез сабак бирә торган фәкыйһлар, мөхәддисләр, әдипләр булган.

Шулай итеп, Бохара дәверендә Муса әфәнде, бер яктан, мәдрәсәләрдә борынгыдан килсә дә, буш, әмма адәм баласының акылын тәмам бутап адаштыру көченә ия булган сафсата белән эш итүче кәлям гыйлемен, гарәп һәм фарсы телләрен, аларның сарыф вә нәхүләрен, ягъни морфология белән синтаксисларын, бәлягать гыйлемен (риторика), мантыйк һәм шәригать хөкемнәренә караган башка кайбер практик белгечлекләрне үзенә кирәк кадәр күләмдә өйрәнә, икенче яктан, шәхси сабак биреп, иҗтиһадлы таләбәләрнең гыйлемгә булган сусауларын канәгатьләндерә алырлык белем ияләреннән мәдрәсәләрдә укытылмый торган фәннәрне үзләштерә.

Мәдрәсәләрдә гасырлар дәвамында үзгәртелмичә укытылган нәрсәләрдән үзгә булган белемне бирерлек мөгаллимнәрдән Бохарада ул чакта дамелла[1] Икрам әфәнде[2], да-

[1] дамелла – үз мәдрәсәсендә дәрес бирә, укыта торган мулла.

[2] дамелла Икрам әфәнде (шулай ук: Икрам домла, мулла Икромча; чын исеме Мөхәммәд Икрам ибн Габдессәлам, 1847–1925) – дин галиме, мөфти, мөдәррис, Бохара мөгаллимнәре арасында иң алдынгы карашлы укытучыларның берсе.

мелла Мир-Шәриф, дамелла Ийваз кебек хәзрәт әфәнделәр яшәгән була. Мир-Шәриф дамелладан Муса әфәнде Эвклид, Фисагурис (Пифагор) һәм Архимед тәгълиматлары белән бергә математикадан дәрес ала, ә Ийваз дамелла белән Икрам дамелла аңа фикъһы һәм фәлсәфәне өйрәтәләр. Шушы елларда Муса әфәнде антик галәмнең иң күренекле фикер ияләре булган Әфләтүн (Платон) белән Аристуларның (Аристотель) фәлсәфәсе, яңа дәвер фәлсәфәчеләреннән булган Декарт белән Бэконнарның фикер дөньясы белән таныша.

Муса әфәнденең хөрмәтле остазлары белән аралашуы ике тараф өчен дә файдалы була: ул алардан гыйлем ала, үз тарафыннан исә аларга, үтенечләрен үтәп, рус теленнән математика буенча кайбер хезмәтләрне, аларны кызыксындырган башка гыйльми әсәрләрне тәрҗемә итеп, гыйлем алуны каракаршы барган һәм һәркем өчен файдалы булган бер хәрәкәткә әйләндерә.

Бохара гарәп телен укыту берникадәр тәртипкә салынган булып, рәсми төстә алып барылган, мәгәр аны укыту методикалары бик борынгы һәм улкадәр үк нәтиҗәле булмасалар да. Ә шәкертләрнең фарсы телен өйрәнүенә аерым туктап алырга кирәк, чөнки, безнең әүвәлге заман дин әһелләренең фарсы телен белүләренә карап, аларның бу телне махсус рәвештә мәдрәсәләрдә өйрәнгән булулары турындагы нәтиҗәгә килергә мөмкин. Тик бу эш алай булмаган. Шуңа күрә Муса әфәнденең Бохарада фарсы телен өйрәнүен һич тә махсус дәресләргә йөреп, фарсы теле дәреслекләрен укып, мөгаллимнәрнең авызына карап утырып өйрәнү буларак күзалларга ярамый. Дини белем бирүнең күп гасырлык традицион методикалары хөкем сөргән Бохарада фарсы теле, гомумән, укытылмаган. Биредә фарсы теле таҗик теле дип аталган җирле шивәдән, ягъни диалекттан гыйбарәт булып, Бохара вә аның әйләнә-тирәсе төбәкләрдә күпчелекне тәшкил иткән таҗикларның туган теле буларак көн күргән. Бу хәл нәкъ татар мәдрәсәләрендә татар теленә карата булган мөнәсәбәткә тәңгәл килә. Казан булсын, Бохара булсын – фарсы телен өйрәнү үзлектән башкарылган: беренчедән, мәдрәсәләрдә

кулланылган дәреслекләрнең бер өлеше фарсы телендә язылган, ягъни телисеңме, юкмы – бу телне белмәсәң, надан булып каласың. Икенчедән, Бохара-Сәмәрканд мәдрәсәләрендә шәкертләрнең, ә урамнарында – халыкның күпчелеге таҗиклар булганга күрә, биредә чын мәгънәдә фарсы телле мохит хакимлек иткән. Мондый шартларда телне өйрәнү шактый җиңеләя. Өченчедән, Шәрык мәдәниятендә, сүз вә әдәбият сәнгатендә иң гүзәл җәүһәр ташларның берсен фарсы шигърияте тәшкил иткәнен дә истә тотарга кирәк. Шуңа күрә шәкертләр арасында шигъри мөназаралар, бәйгеләр, кичәләр үткәрелә торган булган, чөнки шәрык халыкларында шигърият белән кызыксыну, мавыгу, олуг шагыйрьләрнең әсәрләрен ятлап өйрәнү – гадәти бер күренеш, шигъри сүзне ярату, яттан укый белү, шигъри әсәрләр иҗат итү кешене бизи торган зиннәтләрнең иң зәвыклысы, кадерлесе саналган. Муса әфәнде фарсы телен, дини китаплар укудан тыш, шигырь сөюче сабакташлары белән аралашып, шигырь бәйрәмнәрендә катнашып, фарсы шигъриятенең иң мәшһүр классик әсәрләре дөньясында һәм Бохара урамнарында гизеп йөреп өйрәнгән булып чыга. Аның шигърияткә карата гомере буе дәвам иткән мәхәббәте дә, мөгаен, әнә шул елларда уянган булса кирәк.

«*Казан, Мәвараэннәһер мәдарис диниясендә тәкърибән ун сәнә гомереми тәзъйигъ соңында…*», ягъни «Казан, Мәвараэннәһер дини мәдрәсәләрендә якынча ун ел гомеремне әрәм иткәннән соң…», дип язса да, аның Казанда һәм Мәвараэннәһердәге Бохара-и Шәрифтә үткәргән еллары, әлбәттә, әрәм булмаган. Бу дәвердә ул үзенең хәтерен, зиһенен, фикерләү сәләтен, зирәклеген арттырган, мөселман мәгарифенең тарихы һәм хакыйкый хәле белән танышкан, диндәшләренең рухи һәм матди хәлләрен үз күзләре белән күреп нәтиҗәләр ясаган. Бохара елларының тагын бер әһәмиятле үзенчәлеге турында әйтмичә узарга ярамас – ул да булса ислам дөньясының шушы данлыклы тарихи мәркәзендә Муса әфәнденең шәхсияте, акылы, фикер куәте вә рухияте дөрес юнәлештә оешуын, үсешен, ныгуын дәвам иткән.

## Русиядән Госманлы дәүләтенә.
## Муса Акъегетзадә белән күрешү

Якынча 1899 елда Мәвараэннәһердә[1] тәхсыйлен[2] тәмамлап, Муса әфәнде туган ягына – Ростов-на-Донуга әйләнеп кайткач, дөньяви белемнәрен арттыру өчен Петербург университетының ишекләрен кагып карый, әмма латин телен белмәве сәбәпле, студент формасын кию аңа насыйп булмый. Хәер, дөньви белем дигәндә ул заманда эш Русия университетларына гына терәлеп калмаган. Тәвәккәл кеше буларак, Муса әфәнде максатына ирешүнең башка юлын табып Истанбулга китеп бара. Монда ул әлләни кыенлыклар кичермичә югары техник белем бирә торган Мөһәндислек мәктәбенә (хәзерге вакытта Истанбул техник университеты) укырга кереп, ниһаять, студент булу теләгенә ирешә.

Муса әфәнде никадәр тапкыр булмасын, ватаныннан аерылып ерак юлга чыкканда кайларга барасын гына түгел, кемнәр янына да барганын белгән булса кирәк. Бу җәһәттән Истанбулда ватандашы – чыгышы белән Пенза якларыннан булган якташы – танылган татар язучысы Муса әфәнде Акъегетзадә[3] белән күрешүе очраклы хәл булмагандыр дип фаразлавым гайре табигый хәл түгел.

Мусадан ярым дистә ел чамасы олырак булган Акъегетзадә әфәнде 1888 елдан бирле Истанбулда яшәп, шунда ук югары белем алып, биредәге данлыклы «Күлели хәрби мәктәбе»ндә һәм «Мәктәб-е Мөлкия-и шаһанә» университетында урыс теле белән икътисад фәннәрен укытып көн күргән. Әлеге очрашу һәм аралашу яшь Муса өчен эзсез узмаган дип кенә әйтү аз булыр иде. Дөресен әйткәндә, яшь Мусаның олы Муса белән күрешеп сөйләшүләре, аның әле генә дөрес юнәлеш ал-

---

[1] Мәвараэннәһер (гарәп.: Елганың аргы ягындагылар/ Трансоксания) – Амудәрья елгасының (нәһернең) уң яры тарафында, ягъни елганың төньяк-көнбатыш ягында урнашкан җирләр вә далалар.

[2] тәхсыйль – белем алу.

[3] Муса Акъегетзадә (Мөхәммәтҗан углы Муса Акъегетзадә; 1864–1923) – күренекле татар әдибе, журналист, мөгаллим, икътисадчы галим.

ды дип әйтерлек тормыш юлын, техник белем дөньясына таба кереп барган тәкъдирен кискен һәм хәлиткеч сурәттә үзгәртеп, язмышын тәмам башка тарафларга, башка бер галәмгә, башка нәтиҗәләргә табан борып җибәрә: Муса Акъегет үзенең яшь якташына – адашы булган милләттәшенә – дөньяви белем алу урынына дини гыйлем океанына чумып, анда яшеренгән бәһасез рухи җәүһәрләрне ауларга, казанырга һәм ул байлыкларны мөселманнарга ирештереп халыкны агарту, мәгърифәтле итү эшенә алынырга тәкъдим итә.

Әлбәттә, әдип вә бәлягать[1] остасы буларак танылган Акъегетзадәнең Муса әфәндегә әйткән нәсихәтләре тәэсирле дә, үтемле дә булганын фаразлау кыен түгел. Әмма, шуны да аңларга кирәк: әгәр Акъегетзадә хәзрәтләре әңгәмәдәшенең Ходай тарафыннан насыйп ителгән холык вә табигатендә, гакыл вә әхлак сыйфатларында киләчәктә бу егетнең олуг дин галиме һәм мәһабәт фикер иясе булып җитешәчәгенә өмет биргән чаткыларны күрмәсә, бу егетнең никадәр олы гуманистик потенциалга ия булуын сизмәсә, никадәр әдип, психолог булмасын – үгет-нәсихәтем үтемле булсын, дип, тиешле сүзләрне, тиешле интонацияләрне эзләп тә тормас иде.

Икенче яктан, яшь Муса да олы якташыннан ишеткән нәсихәтнең күңеленә хуш килгәнлеген сизгән, чөнки, ни гаҗәп, мәдрәсәдә уку тәҗрибәсе аңа никадәр тискәре тәэсирләр калдырган булса да, ул динне, дини гыйлемне якын күргән. 1907 елда бастырып чыгарган китапларының берсендә Муса әфәнде Кодрәт иясе булган Аллаһ тарафыннан аның күңеленә дини гыйлемнәрне ярату орлыклары утыртылган булуын ассызыклап: «*Дәст(е)*[2] *Кодрәтлә*[3] *калебемдә голүм динийәйә*[4]

---

[1] бәлягать – сөйләм теленең төзек һәм аңлаешлы булуы, аның матурлыгы, тәэсирлелеге, үтемлелеге.

[2] Дәст (دست) – кул.

[3] Кодрәт (قدرت) – биредә: һәрнәрсәне булдыра алучы Аллаһ. Дәст(е) Кодрәт (دست قدرت) – Һәрнәрсәне булдыра алучының кулы.

[4] голүм динийәйә (علوم دينيه) – дини голүмнәргә (гыйлемнәргә, фәннәргә).

*мәхәббәт хәббәсе*[1] *гарес*[2] *улынмыш...*» – дип язган. Акъегетзадә дә, якташына нәсихәтен биргәндә, әнә шул орлыкларның, шытып чыгып, киләчәктә никадәр бәрәкәтле җимешләр бирәчәген күңел күзе белән күрә алган.

Ихтималдыр ки, әгәр күңеле түрендә яңгырап торган бу илаһи авазны санга сукмыйча, аңа «колак салмыйча», ул кушканны үтәмичә һаман да шул дөньяви белем, дөньяви шөгыльләр юлыннан баруны сайлаган булса, без, бәлки, Муса Бигиев дигән кеше турында белмәс тә идек. Әмма, шөкер – хикмәт иясе булган Аллаһы тәгаләнең әмере белән яшь Мусаның юлына чыгарылган һәм аңа тиешле киңәшләрен биргән Акъегетзадә хәзрәтләрен дә без Муса Җаруллаһ Бигиев кебек могътәбәр шәхеснең барлыкка килүенә зур, хәтта хәлиткеч өлеш керткән кеше дип карый алабыз.

## Мисыр, Хиҗаз вә Һиндестанга сәфәр

Муса әфәнде Истанбулда язмышын «иске яңа» юлга кертеп җибәргәннән соң, Госманлы Дәүләти Галиясенең әкияти биләмәләреннән берсе булган Мисырга юл тота. Бу турыда болай язган: «*...кадер(не)ң*[3] *сәвыкыйлә*[4] *шәвык(ны)ң*[5] *кыйадәсейлә*[6]*, хыйалым бөек өмидләрлә мәмлүъ икән*[7]*, биляд исламийәйә*[8] *сәфәр итмеш идем*».

---

[1] хәббә (حبه) – орлык бөртеге.

[2] гарыс (غرس) – орлык утырту, орлык чәчү.

[3] кадер(не)ң (قدرڭ) – язмышның; кадер (قدر) – язмыш.

[4] сәвыкыйлә (سوقيله) – алга этәрүе белән; сәвык (سوق) – алга этәрү, куу, сөрү; юнәлтү.

[5] шәвык(ны)ң (شوقڭ) – көчле теләкнең; шәвык (شوق) – көчле теләк.

[6] кыйадәсейлә ((قيادهسيله – җитәкчелеге белән; кыйадәт (قيادت) – җитәкчелек; идарә итү; йөртү.

[7] мәмлүъ икән – тулган хәлдә; мәмлүъ (مملوء) – тулы ителгән; тутырылган.

[8] биляд исламийәйә (بلاد اسلاميهيه) – ислами илләргә; биляд (بلاد) – илләр.

Гыйлем эстәү юлына чыккан яшь егетнең бу адымы аңлашыла да: Мисырның башкаласы – йөзләгән мәчетләренең меңләгән манараларын күккә ашырган борынгы гүзәл Каһирәдә ислам дөньясының йөзек кашы булган иң данлыклы, иң абруйлы дини белем бирү үзәге – «әл-Әзһәр»[1] университеты ул чакта эшчәнлегенең инде унынчы гасырын башлаган була. Муса әфәнде әле һаман да дөньяда сыйфатлы дини белем учагының барлыгына өметләнеп шунда ашыга һәм бирердә өч ел дәвамында дини гыйлем ала. Тик мактаулы «әл-Әзһәр»дә дә Муса әфәнденең өметләре акланмый. Ул Бохарада кулланган гыйлем туплау ысулын Каһирәдә дә файдалана: берникадәр дәресләрне – университетта, калганнарын гыйлем ияләреннән шәхси дәресләр рәвешендә ала. Шулай итеп, Муса әфәнде танылган дин галиме, Мисыр мөфтие Мөхәммәд Габдүһ (1849–1905), «әл-Әзһәр» университетының иң күренекле остазларыннан булган дин галиме шәех Бахит әфәнде (1854–1935), Мисырның атаклы дин һәм җәмәгать эшлеклесе, нәшриятчы Мөхәммәд Рәшид Риза (1865–1935) белән таныша һәм алардан сабак ала. Бу кадәр зур шәхесләр һәм дин галимнәре белән аралашу, әлбәттә, Муса әфәнденең фикер сөрешенә, дөньяга, җәмгыять тормышына һәм дингә карата булган карашларына тәэсир итми калмаган.

Моннан тыш, 1904 елда ватанына әйләнеп кайтканчы Мисырда үткәргән елларында Муса әфәнде алга таба гомере буенча дәвам ителәчәк мәсләкләреннән берсен – Коръәнгә багышланган тикшеренүләрен башлап җибәрә. Аерым алганда, Каһирә китапханәләрендә ул Коръән тарихы мәсьәләсен өйрәнүгә кереп китә һәм бу фәнни эштә уңышлы нәтиҗәләргә

---

[1] «Әл-Әзһәр» – җир йөзендә эшләп килгән иң борынгы университетларның берсе: уку йорты 970 елда «Әл-Әзһәр» мәчете каршындагы мәдрәсә буларак эшли башлый, 988 елда Фатыймачылар династиясе хөкемдарлары тарафыннан рәсмиләштелереп, шигыйлыкны тарату үзәге буларак хезмәт итә. Саляхетдин әл-Әйүби Фатыймачыларны тар-мар иткәч, 1171 елдан «Әл-Әзһәр» сөнни ислам мәркәзенә әйләнә.

килеп, югарыда искә алынган елда Русиягә әйләнеп кайтыр-кайтмас әлеге тема буенча бер китап та бастыра.

Шул елларны искә алып, ул болай дип язган: «*Каhирәдә... бик озак вакыт калдым. Күфи язуы белән язылган борынгы мосхәфләрдән 7 данәсен укыдым. Көтепханәләрдә күп китап укыдым. Тәурат сахибы Муса пәйгамбәрнең мөкатдәс Турын күрү, анда бераз игътикяф итү теләге калебемдә җанланды. Якында ул якларга да хәрәкәт итәчәкмен. Акчам юк, шулай да барам. Диңгезнең ул тарафларын да җәяүләп йөреп чыгармын иншаллаh*»[1].

Кайбер чыганакларга караганда, Истанбулдан Мисырга киткән Муса әфәнде бер урында тукталып калмый һәм, гыйлем сәфәрен дәвам итеп, Хиҗазда урнашкан изге Мәккә белән Мәдинә шәһәрләренә дә барып чыга. Бу шәһәрләрнең икесендә дә берәр ел дәвамында яшәп, андагы дини белем бирү тәртипләре белән таныша, җирле галимнәр белән очраша, алардан сабак ала. Күп еллар узгач язган бер хатында, шәкертлек елларын исенә төшереп, ул болай дип язган: «*Шәкерт чагымда Мәккә-и Мөкәррәмәдә 18 ай кадәр яшәдем. Күз карашым һәрвакыт йә Кәгъбә хозурында, яки Җәбәлән-Нурда, Гар*[2] *эчендә булыр иде. Бөек нәбилек мәдрәсәсенең шәкерте булу бәхете миңа да насыйп булды. Хәятемдә иң кыйммәтле, иң бәрәкәтле вә иң тәэсирле дакыйкаларым бу Гар дакыйкаларыдыр. Һиҗрәт гарында иптәш булу, яр булу шәрәфе бары тик Әбу Бәкер Сиддыйк хәзрәтләренә махсус бөек бер сәгадәт иде исә Нур Гарында, Рисаләт илаhия мәктәбендә, шәкертлек бәхете миңа да насыйп булды. Шө-*

---

[1] Uralgiray. Yusuf Uralgiray. Üstâdimiz Musa Cârullah’ın «Finlandiya Cemaat İslâmiyesi» başkanı hafiz imam Veli Ahmed Hakîm hazretlerine muhtelif tarihlerde yazdığı mektuplar. S.20. (Алга таба: Uralgiray. Mektuplar).

[2] Гар – Җәбәлән-Нур тавында урнашкан тау куышы, мәгарә. Шул мәгарәдә игътикяф кылган чагында Мөхәммәт пәйгамбәргә (ﷺ) беренче вәхи иңә.

*кер хиссияте белән калебем һәрвакыт Әбәдияткә кадәр*[1] *моның белән горурланыр»*[2].

Хиҗаздан соң язмыш юллары Муса әфәндене Һиндестанга, дөресрәк әйткәндә – Британия Һиндестанына китерә. Биредә ул Диюбәнд шәһәрендә урнашкан һәм абруй вә дәрәҗәсе белән «әл-Әзһәр» университетының тиңдәше булган «Дар әл-Голүм Диюбәнд» («Диюбәнд гыйлемнәр йорты») исемле ислам университетында өч ай дәвамында гыйлемен арттыра. Моннан тыш, ислам дөньясының әлеге экзотик бер кыйтгасында Муса әфәнде гыйльми мөназараларда катнаша, дин әһелләре вә галим-голәмә белән таныша, яңа дуслар таба. Борынгы һәм искиткеч бай ислам мәдәнияте учагы булганга күрә, Һиндестанның китапханәләре дә, әлбәттә, Муса әфәндене игътибарыннан читтә калмый. Һәм Һиндестанда Муса әфәндене дикъкатен җәлеп иткән тагын бер нәрсәне әйтми калу дөрес булмас иде: биредә ул тарихларда кайчан башланганы гайре мәгълүм булган һиндчылык диненең изге китапларын укыр өчен санскрит телен өйрәнә башлап, ул китапларны укырлык дәрәҗәдә аны үзләштереп өлгерә. Гомумән алганда, Муса әфәнде башка диннәргә карата бик игътибарлы һәм ихтирамлы булган, аларның барысын да ул кешелек дөньясының рухи үсеше дәвамында үткән этаплар итеп күрә. Болай булмаса, аның китапларында Будданың Аллаһ пәйгамбәре булуы, Ведаларның сәмави, ягъни күктән иңдерелгән изге китаплар булуы турында фикерләр, әлбәттә, очрамас иде.

Һиндестан белән танышканнан соң, Муса әфәнде Шам Шәрифне айкап чыга, кабат Каһирәгә килеп төшеп, биредә Коръән тарихына багышланган тикшеренүләрен дәвам итә, соңыннан инде кайтыр юлга чыккач, яңадан Госманлы Дәүләти Галиясе биләмәләрен зиярәт итә.

---

[1] Әбәдияткә кадәр – Мәңгелекккә кадәр, ягъни мәңге дәвам итәчәк Ахирәткә (Ахирәт башланганчыга) кадәр.

[2] Uralgiray. Mektuplar, s. 20.

## Гыйлем сәфәренең нәтиҗәләре

Муса әфәнденең бу «гыйлемләнү сәфәре», әгәр аны «Күл буе» («Касыймия») мәдрәсәсендә укый башлаган 1888 елдан саный башласак, 1904 елга кадәр дәвам итеп, җәмгысы 15 ел тәшкил иткән булып чыга: «*Шу хәлдә унбиш сәнә*[1] *биляд исламийәйи, мәдарис динийәләрене тулашдым*»[2], дип язган шәкертлек чоры тәмамлана. Шул исәптән, чит илләрдә тәхсыйленең дәвамы исә якынча 5–6 ел тәшкил итә.

Муса әфәнденең ислам дөньясын еллар дәвамында иркенләп гизүе, әлбәттә, күңел ачу, тамаша кылу өчен башкарылган бер туристик сәфәр түгел. Бу елларны ул ислам җәмгыятенең вазгыяте белән танышуга гына сарыф итмичә, гыйлем туплау буенча да үтә дә киренке хезмәттә үткәргән. Гомумән, тәхсыйль[3] елларында Русиядә тууны карар кылган тәкъдир аңа, берьяктан, борынгы төркилектә тамырланып, ислам белән үрелеп үскән татар-мөселман мәдәнияте, икенче яктан, Көнбатышка мәйел булган рус мәдәниятләре белән якыннан танышырга мөмкинлек бирә. Бу үзенчәлек, шиксез, Муса әфәнденең дөньяга карашына да, акыл вә зиһененә дә, психикасына да тәэсир итә. Ул традиционлык кысаларында бикләнеп калмыйча, иркен сурәттә һәр мәдәниятнең уңай һәм алдынгы хосусыятьләрен файдалана: шәркый мөселман мохитенә хас рухи байлыкларны да, рус мәдәнияте казанышларын һәм аның аша Зур Көнбатышның цивилизацион хәзинәләрен дә үзенеке кебек иркен куллана. Һәм, тагын бер үзенчәлек: Муса әфәндене гыйлем вә фән дөньясында бары тик дини гуманитар мәсләкләр генә кызыксындырмаган. Ул риязый фәннәрне дә, ягъни математика, физика, химия, астрономия, география, биология һәм башка өлкәләргә караган дисциплиналарны да игътибарыннан читтә калдырмаган. Шулай итеп, Муса әфәнде ислам дөньясында җитешкән бихисап галимнәрнең дә, рухи үсешнең югары дәрәҗәләренә ирешкән мөселман фикер ияләренең дә, ватандашлары булган

[1] сәнә – ел.

[2] тулашдым – гиздем.

[3] тәхсыйль – гыйлем алу; белем туплау.

рус галимнәренең дә, Мейер, Карлайл, Шпренгер, Мюллер, Вайль, Гольдциер, Вольтер, Ренан кебек Көнбатыш галимнәренең дә хезмәтләрен өйрәнгән һәм үзенә кирәкле сурәттә аларны кулланган. Муса әфәндене һич тә икеләнмичә ислам дөньясының соңгы энциклопедист-галиме дип атарга була. Тәхсыйль дәверендә аның никадәр тәҗрибә туплаганы, никадәр гыйльми һәм фәнни эш башкарып чыккан, никадәр белем туплаган булуы ватанына кайтканнан соң бер-бер артлы басылып чыккан хезмәтләренең эчтәлегеннән бик тә яхшы күренә. Мәсәлән, аның мондый сүзләре сакланган: «*Төркия, Мисыр, Хиҗаз, Һинд, Шам әкътар исламийәләрендә галәт-тәртиб тәкърибән биш сәнә мөддәт сәйер идүб; шу билядләрнең мәдарис динийәләрендә, аз йә чук, икамәт идәр идем. Шу мәмләкәтләрдә намлары мәшһүр мәдарис динийәләр(не)ң һәрберене күрдем. Фәкать, тәәссеф, у «бөек дини мәдрәсәләрдә» иң аз шәй голүм динийәйи булдым… Һичбер мәдрәсә динийәдә кадәр-е кифайә голүм динийә буламадым. Дәрес(е) Китаб, дәрес(е) сөннәти, һәммә мәдрәсәләрдә гүя бер дәрәҗәдә, накыйс күрдем. Гакыйбәт, канәгатьлә дәгел тәмам хәйрәтлә, ватаныма кайтдым*», ягъни биш ел дәвамында Төркия, Мисыр, Хиҗаз, Һинд, Шамнарның данлыклы мәдрәсәләрен айкап чыккан Муса әфәнде дин гыйлемнәренең ул мәдрәсәләрдә иң аз булган нәрсә икәнлеген үз күзләре белән күргән, Коръән сабагының, сөннәт-хәдис дәресләренең һәркайда бер дәрәҗәдә аз булуы турындагы нәтиҗәгә килгән. Ниһаять, канәгатьләнү хисе белән түгел, тәмам аптыраган хәлдә ватанына кайткан.

Әмма, ни генә булса да, 1904 елның икенче яртысында шактый күпне өйрәнеп, аннан да күпне күреп, тормыш тәҗрибәсе туплап, гомеренең өченче дистәсен тәмамлап килүче Муса әфәнде Бигиев туган иленә әйләнеп кайта һәм тәрҗемәи хәленең яңа бүлеген ачып җибәрә.

# Икенче фасыл:
# 1904–1916 елларда Русиядәге тормышы

## Туган иленә кайту. Өйләнүе

Гомеренең бу өлешен Муса әфәнде Русия империясенең башкаласында – Санкт-Петербург, соңрак, Петроград, аннан соң Ленинград исемнәре белән аталган пайтәхет калада үткәрә. Бу шәһәрдә ул ватанына әйләнеп кайткан 1904 елдан башлап, Советлар илен ташлап китәргә мәҗбүр булганчы, ягъни 1930 елның кара көзенә кадәр яшәгән. Чит илләрдән кайткач, беренче эше итеп, Ростов-на-Донуга барып әнисенең кулларын үбә, берничә көн бирелә кунак булып ала.

Күрсәтелгән еллар арасында Муса әфәнде тәкъдир асыл мәсләге иткән эшләр белән мәшгуль була: дини, әдәби, фәлсәфи иҗат дөньясына кереп китә, милләтенә, дин кардәшләренә, гомумән, ислам диненә фидакяр хезмәт итә, ил буенча күп йөри. Бу елларда Муса әфәнде үзенең иң танылган һәм әһәмияттен әлегә кадәр югалтмаган китапларын яза, Коръән кәримне татар теленә тәрҗемә итә, татар публицистикасында тирән эз калдыра, мөгаллим буларак, үз исемен милли-дини мәгариф тарихы сәхифәләренә язып, шәхси дәресләр бирергә дә вакыт табып, совет дәверендә мәртәбә казанган күренекле шәркыятьче галимнәр тәрбияләп калдыра, Петроград Җәмигъ мәчетендә имамлык итә, 1905 елдан башлап күтәрелеш кичергән милли-дини тәрәккыятьнең сәяси көч буларак формалашуы процессының үзәгендә торып, Русия мөселманнарының корылтайларында, съездларында актив катнаша, протоколларын теркәп, аларны нәшер итеп тора, чит илләрдә Совет мөселманнарының вәкиле буларак ватанына һәм гомум ислам өммәтенә хезмәт итә, бу эшләре өчен кулга алына, төрмәләрдә утыра, сөргеннәргә сөрелә. Кыскасы, тормышында иң киеренке, иң

эшлекле, иң нәтиҗәле чор була бу. Аның туган илендә яшәгән әлеге дәверендә булып кичкән вакыйгалар бер адәм тормышына ничек сыеп бетә алган икән дип хәйран калырлык.

1905 елда, май аеның 20-сендә, Муса әфәнде гаилә корып җибәрә. Пәйгамбәребез Мөхәммәтнең сөннәтеннән килгән бу гамәл аның туган иленә кайтканнан соң эшләгән беренче эшләреннән була: Ростов-на-Донуда әнисен күреп сөендереп, шул ук шәһәрдә җирле мөселманнар тарафыннан аңа имамлык кылу тәкъдимен кире кагып өлгерә дә, озакка сузмыйча Чистайга – сөйгән яры белән күрешергә ашыга. Аның булачак хәләл җефете Чистай шәһәре мәчетендә имамлык, мәдрәсәдә мөдәррислек иткән данлыклы Закир ишан[1] Камаловның кызы Әсма-Галия туташ була.

Егет белән кызның кавышу тарихы Муса әфәнденең Мисырда укыган елларына барып тоташа: Каһирәдә аның белән бергә тагын берничә татар егете белем ала. Мәсәлән, киләчәктә күренекле дин галиме, фикер иясе, мөгаллим булып җитешкән, Уфада «Галия» мәдрәсәсенә нигез салып шуны җитәкләгән Зыяэтдин Кәмали белән Муса әфәнде нәкъ менә әл-Әзһәрдә укыган елларда таныша. Зыя Кәмали турында сүз алга таба да булыр, ә хәзер безне шундый татар шәкертләреннән тагын берсе – Закир ишанның угылы Ибраһим Камалов[2] кызыксындыра. Ерак илдә өч-дүрт бөртек ватандашның

[1] Закир ишан (Габделваһаб углы Мөхәммәт-Закир Камалов / Закир ишан Чистави; 1804–1893) – Чистай шәһәрендә шәхси чыгымнары исәбенә мәчет салып, 1946 елдан башлап гомеренең ахырына кадәр шунда имам-хатыйб булып хезмәт иткән дин әһеле, «Камалия» мәдрәсәсен ачып, шунда дин сабагы биргән мөгаллим, накышбәндия тарикатенең шәехе, меңләгән мөритләренә Аллаһка якынаю юлларын ачкан, даны бөтен Русия мөселманнары арасында танылган мөршид. Закир ишанның Коръәнне һәм ислам динен белүенең тирәнлеге замандашларын тәмам сокландырган дәрәҗәдә булып, аның фәтва-хөкемнәре һәм нәсихәтләре пәйгамбәр авызыннан чыккан сүз дәрәҗәсендә кабул ителгән.

[2] Ибраһим Камалов (Закир углы Ибраһим Камалов; 1877–1938) – Чистай каласының 1 нче мәхәллә мәчете имам-хатыйбы, совет дәвере репрессияләре корбаны.

якын дуслар булып китүе табигый булганга күрә, Ибраһимның сеңлесе Әсмадан килгән хатлардан дусларына парчалар укып ишеттерүе дә сәер түгел. Муса әфәнденең кызы Фатыйма ханымның хатирәләре буенча, бу хатларның никадәр тирән эчтәлекле, акыллы, күңелле булуына сокланган Муса Ибраһимнан сеңлесе белән таныштыруын үтенә. Ибраһим каршы килми һәм егет белән кыз тиз арада бер-берсенең фотосурәтләрен күрәләр, күргәннәре күңелләренә хуш килә. Уйлап карасаң, татар мохите өчен егет белән кызның бу рәвешле танышулары, әлбәттә, гореф-гадәт кысаларын исәпкә алмаган. Ни генә булса да, иленә кайтыр-кайтмас борын Муса әфәнде Чистайга юл тота һәм Әсма-Галия туташның әнисе Фатыйма ханымнан кызын үзенә хәлал җефет итеп алырга рөхсәт сорый. Итәгатьле, тәрбияле, белемле Муса Фатыйма ханымның күңелен тиз яулаган булса кирәк – озак та үтми, яшьләргә никах укылып, шул ук Чистай каласында зур, күңелле туй да үткәрелә. Муса әфәнденең бу туе турында Әхмәт-Зәки Вәлиди Тоган әле яшь чагында «*…бер шәехнең заманча тәрбия алган кызы белән заманча туй мәҗлесе үткәреп өйләнгәнен*» ишеткән булуы турында үзенең «Tasvir» гәзитендә басылган истәлекләрендә язган.

Әйтергә кирәк ки, Муса әфәнде белән Әсма-Галия ханымның туйлары Чистай каласында узган тантана гына түгел, аңа Русия мөселман җәмәгатьчелеге тарихында да әһәмиятле бер вакыйгага әйләнергә насыйп була. Татарлар арасында сәяси хәрәкәт инде күптән башланганга күрә, мулла Ибраһим Камаловның булачак кияүләре һәм дусты Муса әфәнденең туган сеңлесе Әсма-Галия белән никах көннәрен тәгаенләр өчен Петербургка килүе дә шул хәрәкәтнең бер эпизоды булып каралырга хаклы. Форсаттан файдаланып, Камалов ул көннәрдә башкалада җыелган мөселман сәяси активистларын 20 майда Чистайга кунакка – Муса Бигиев белән Әсма Камалованың туй мәҗлесенә чакыра. Туйда бәйрәм итү белән бергә, Русия мөселманнарын борчыган мәсьәләләр турында зур сөйләшү үткәреләчәге турында да кисәтә. Шулай итеп Чистайга биш йөзләп туй кунагы килеп төшә: арада зыялы, алдынгы караш-

лы, дәртле-гайрәтле, милли мәдәният, дин, мәгърифәт, матбугат өлкәләрендә инде танылып өлгергән милләтпәрвәр затлар күп булганлыктан, туйдагы сохбәтләр милли яңарыш, Русиядә татар вазгыяте, милли мәгариф, дин мәсьәләләре кебек мәүзуглар турында була. Нәтиҗәдә, нәкъ менә шушы туй барышында Бөтенрусия мөселман корылтае үткәрелүенең кирәкле һәм вакыты җиткән бер чара булуы турында фикергә киленә.

Чистайда 20–22 майда үткәрелгән киңәшмәнең Казан губернасы жандарм идарәсе документларында «1 нче мөселман корылтае» (1-й мусульманский съезд)[1] дип аталуы, бер яктан, әлеге вакыйганың тарихи масштабын яхшы күрсәтә. Икенче яктан, татар халкының һәм ислам диненең киләчәгенә карата зур планнар корып иленә кайткан, омтылыш вә ниятләрен тормышка ашырыр өчен җиң сызганып эшкә тотынган Муса әфәнденең хәтта туе да Русия мөселманнарының иҗтимагый тәрәккыятенә хәлиткеч тәэсир ясаган символик бер вакыйгага әйләнүе игътибарга лаек.

Муса әфәнде белән Әсма-Галия ханым алты бала: ике ир һәм дүрт кыз үстереп аякка бастыралар. Әмма фаҗигале югалтулар да булмый калмый, ике баланың, шул исәптән беренче уллары Әхмәтнең рухлары сабый чакларында ук Аллаһ хозурына күчә. Исән калган балаларының исемнәре һәм яшәгән еллары ошбулардыр: Мәрьям (1907–1993), Зәйнәп (1908–1967), Мөхәммәт (1909–1941), Һинд (1911–1962), Әхмәт (1912–1947дән соң[2]), Фатыйма (1918–2006)[3].

Мал-мөлкәтенә килгәндә, Муса әфәнденең үз сүзләренә күрә, аның исәпкә алынырлык күчемсез малы, сәүдә-фәләне

---

[1] Загидуллин И. К. Гаяз Исхаки в петиционной кампании мусульман 1905 года // Гаяз Исхаки и национальное возрождение татар в начале XX века: материалы международной конференции, посвященной 140-летию со дня рождения Г. Исхаки / сост.: Ф. Х. Миннуллина, А. Ф. Ганиева, Л. Р. Надыршина.– Казань: ИЯЛИ, 2018.– С. 186–192.

[2] Муса углы Әхмәт Бигиевнең язмышына кагылышлы өстәмә мәгълүмат китапның 1947–1948 елларга караган өлешендә бирелә.

[3] Мәгълүматны Муса әфәнденең оныгы (Һинд исемле кызының кызы) Алия ханым Янгирова хәбәр итте.

булмаган. Инде искә алынган беркетмәләрдә ул үзе язган китапларны сату исәбенә көн күрүен белдергән. Чыннан да, матди хәлнең кысынкы булуына күрә, өйләнгәннән соң яшьләр байтак еллар дәвамында оя кора алмыйча яшиләр – Әсма-Галия ханым балалар белән көннәрен әнисе янында Чистайда, Муса әфәнде исә Санкт-Петербургта, Русия буйлап туктаусыз сәфәрләрдә үткәрә.

## Беренче китабы

Муса әфәнденең «***Таъриху әл-Куръәни вә әл-мәсахифи***»[1] («Коръән һәм мосхәфләр тарихы») дип аталып, Коръән белеменә караган беренче китабы 1905 елда Санкт-Петербургта И. Бораганский[2] матбагасында дөнья күрә.

Русиядә басылган беренче китабы «Таъриху әл-Куръәни вә әл-мәсахифи»не Муса әфәнде гарәп телендә язган. Күрәсең, үзенең дин галиме буларак башлаган эшчәнлегенең кәгазьгә ятып китап рәвешендә дөнья күргән җимешләрен башта мөселманнарның күпчелегенә, бигрәк тә зыялыларына, аңлаешлы булган гарәп телендә язу ниятендә булган. Һәрхәлдә, алга таба Муса әфәнде каләме астыннан чыккан тагын берничә әсәр шундый була. Әмма бик тиз арада ул китапларның кереш сүзләрен булса да татар теленең госманлы шивәсендә яза башлый, соңрак исә Русиядә бастырган һәр әсәрен бары тик шушы телдә язуга күчә.

---

[1] Муса Җарулла Рустуфдони. Таъриху әл-Куръәни вә әл-мәсахифи. СПб.: Тип.– Лит. И. Бораганского и Кº, [1905]. 38 с.

[2] И. Бораганский (Ильяс морза Бораганский; 1852–1942) – чыгышы белән Кырым татарларыннан булган мәгърифәтче, җәмәгать эшлеклесе, иганәче, хөсне-хат остасы (1880 елларда Русия Тышкы эшләр министрлыгының рәсми каллиграфы булып хезмәт иткән), мөгаллим һәм төркиятче галим (1898–1908 елларда Петербург университетының Шәрык телләре факультетында төрек-татар телләре кафедрасында лектор булып эшләгән), нашир, (1983 елда Санкт-Петербургта «Восточная электро-печатня» дип аталган беренче мөселман матбагасы ачып китаплар бастыра), гомумән алганда, китап нәшер итүгә гомеренең 50 елын багышлаган.

Күләме зур булмаса да, гарәп телендә язылган булуы сәбәпле «Таъриху әл-Куръәни вә әл-мәсахифи» чит ил мөселманнарының да игътибарын җәлеп итә: әлеге хезмәтне Мусаның Мисырдагы остазларыннан берсе Рәшит Риза әфәнде 1907 елда үзенең «әл-Мәнар»[1] журналында бастыра. Тышкы ислам дөньясының мәшһүр мөҗәддидләре тарафыннан да хупланып каршы алынган бу әсәр аларны нәрсәсе белән кызыксындырган икән? Бу сорауга җавап бирү йөзеннән түбәндәгеләрне әйтеп була.

Гомумән алганда, җисеме исеменә туры килеп, анда Коръән тарихы, ягъни изге китапның вәхи буларак иңгән чагында ук беренче мөселманнарның хәтерендә һәм язуда теркәлүе, аннары аның мосхәф, ягъни безгә таныш китап шәкеленә китерелүе бәян ителә, Коръәннең игъҗазы, ягъни һичкем тарафыннан аңа тиң булырлык бер генә җөмлә дә иҗат итә алмавы аңлатыла, язуда теркәлү үзенчәлекләре һәм кагыйдәләре, сүрә вә айәтләрнең тәртипләре турында сүз йөртелә. Болар барысы да китапның төп өлешендә китерелә, һәм бу нәрсәләр, беренче нәүбәттә, махсус сурәттә гыйльме Коръән белән тирәнтен шөгыльләнеп, бу гыйлемдә югары дәрәҗәдәге осталыкка инде ирешкән яки ирешергә теләгән белгечләр өчен кызыклы. Гади халык өчен, миңа калса, китапның 11 сәхифәлек, ягъни өчтән берен диярлек тәшкил иткән кереш сүзе файдалы булачак, чөнки анда ислам дөньясын бимазалаган проблемалар һәм аларны хәл итү юллары билгеләнә. Аерым алганда, сүз мәктәп вә мәдрәсәләрдә уку-укыту системасының җитешсезлекләре, балаларны тәрбияләү эшенең яман булуы һәм мәгариф белән шөгыльләнүчеләрнең эшкә ярамаулары турында бара. Муса әфәнде башта шәригать таләпләренә туры килгән ислам мәгарифе вә тәрбиясенең нинди булырга, нинди нәтиҗәләргә

---

[1] «Әл-Манар» – Каһирәдә 1989–1935 елларда чыккан гарәп телле дини журнал. Журналга нигез салучы һәм аның баш мөхәррире Рәшид әфәнде Риза (1865–1935) аның сәхифәләрендә дини яңарыш һәм ислам халыкларының бердәмлеге идеяләрен таратырга омтылган. Шулай ук журналда Коръән тәфсирләренә зур игътибар бирелгән. Ризаның вафатыннан соң журнал чыгудан туктый.

китерергә тиешле булуы турында хәбәр биреп, әлеге иҗтимагый төшенчәләрнең теоретик нигезләрен бәян итә. Аннан соң игътибарын чынбарлыкка юнәлтеп, андагы хәлләрне болай сурәтли: «*Безнең дини дип санаган мәктәп-мәдрәсәләребез бар. Аларда гарәп теле грамматикасыннан аз-маз гыйлем бирелә, мәзһәбләр арасындагы аермалар һәм иман нигезләре турында, шул исәптән, иң яман тәртипкә салынган рәвештә буш лафлардан торган кяләм гыйлеме һәм фәлсәфи уйдырмалар мул итеп «белем» бирелә. Тырыш шәкерт андый мәдрәсәдә дистәләгән еллар үткәреп, укыган дәверендә үзләштергән гадәтләр аркасында акыл ягыннан да, әхлак ягыннан да тәмам бозылган хәлгә килеп аны тәмамлый. Аның хисләре тупасланган була, андый мәдрәсәдә сәламәтлегенә һәм исәнлегенә килгән зыянның күплеге аркасында кеше тәмам зәгыйфьләнгән була*»[1].

Әлеге сүзләрдән аңлашылганча, дини мәгариф системасында гасырлар дәвамында өсте-өстенә өелеп килгән проблемаларны хәл итү эшен Муса әфәнде дини, милли, мәдәни, әхлакый, рухи яңарышның нигез шарты итеп күргән. Мәгариф системасын үзгәртеп коруны исә ул яхшылап Коръәнне өйрәнүдән башларга кирәк дип санаган. Бу аңлашыла да – Коръән мөселманны дөрес уйларга, дөрес сөйләргә, дөрес гамәлләр кылырга өйрәтә, ягъни Коръән – ислам дине вә гыйбадәтнең генә нигезе түгел, тормыш коруның да, көн күрүнең дә нигезе булырга тиешле китап. Нигезнең ни булуын мөселманнар әгәр белмәсәләр, аны аңламасалар, нинди тәрәккыять турында сүз була алсын ди? Муса әфәнденең искә алынган китабы шушы мәсьәләне хәл итүгә таба атланылган адымнарының беренчесе булып тора.

### Габдерәшит Ибраһим белән танышу. «Өлфәт», «Әт-Тилмиз»

Шул ук 1905 елның май аенда, Чистайда гөрләп туй иткәннән соң, бер атна үтәр-үтмәс, Муса әфәнде башта Казанга, аннары Троицк, Ростов-на-Донуларга сугыла да Санкт-Петербургка китеп бара.

[1] Өзек татар теленә тәрҗемә ителде.

«Муса әфәнде яшәр урыны итеп ни өчен нәкъ менә Санкт-Петербургны якын күргән икән?» дигән сорауга җавап бирәсе булса, мин болай дияр идем: беренчедән, Санкт-Петербург – бөек империянең башкаласы. Чыннан да, Истанбул, Каһирә кебек борынгы, мәһабәт, чал тарихны заманавилек белән кушып кайнап торган казан кебек дөрләп яшәп яткан цивилизация үзәкләрен күреп, шунда яшәп, икмәген ашаган, суын эчкән Муса әфәнде, әлбәттә, Русиянең провинциаль бер шәһәрендә күкрәгендә кайнап торган дәрткә, ташып торган егәренә лаеклы эш, муафыйк шөгыль таба алмас иде. Икенчедән, башкала икән, димәк андадыр тарих сәхифәләренә вакыйгалар сугып, заманны, ил язмышын, шул исәптән татар хәятен дә хәрәкәткә китереп торган тимерчеханә. Шулай була да: кайбер тикшеренүчеләрнең фикеренә күрә, Муса әфәнде Санкт-Петербургны шунда яшәп, киеренке иҗтимагый хезмәттә җигелеп эшләп яткан Габдерәшит казый Ибраһимов[1] белән танышыр, аның белән бергәләп милләт мәслихәтләрен кайгыртыр өчен сайлаган. Өченче сәбәп – университет, Муса әфәндене бик тә кызыксындырган юриспруденция фәне буенча белем алу перспективасы була. Чыннан да, бу шәһәрдә ул, ниһаять, император университетының юридик факультетына «вольный слушатель» буларак укырга керә. Болай булуы бик ихтимал: аннан алдагы елларда хәтта санскрит телен өйрәнә башлаган Муса Бигиев, ни генә булса да, латин телен өйрәнмәгән, димәк, университетка керер өчен бу телдән имтихан да тапшыра алмаган, ирекле тыңлаучылыкны сайлаган. Муса әфәндене университет студенты униформасын киеп, Казан урамнарында йөргәнлеге замандашы булган Әхмәт-Зәки Вәлидинең хатирәләреннән мәгълүм. Димәк, «вольный слуша-

[1] Габдерәшит Ибраһимов (Гомәр углы Габдрәшит Ибраһим; 1857–1944) – күренекле татар мөселман сәясәтчесе, дин һәм җәмәгать эшлеклесе, татар милли азатлык көрәше эшлеклесе, дин галиме, күпсанлы китаплар авторы, сәяхәтче. Дини белемне Себер мәдрәсәләрендә һәм Казан төбәгендәге Кышкар мәдрәсәсендә (1877) ала, 1879–1884 елларда Мәдинә шәһәрендә дә белемен камилләштерә, Коръән-хафиз булып чыга; 1892–1895 елларда Уфадагы Үзәк Диния нәзарәтендә баш казый булып хезмәт итә.

тель» булу да студент униформасын киеп йөрергә мөмкинлек биргән булып чыга.

Муса әфәнденең Русиядә үткәргән еллары аның сәяси хәрәкәттә, сәяси эшчәнлектә ныклап катнашуы белән дә тарихка кереп калган. Табигый ки, аның сәясәт даирәсендәге беренче тәҗрибәләре Санкт-Петербург белән бәйле. Империянең башкаласы татарлар яшәгән җирләрдән шактый ерак урнашса да, әлеге шәһәрдә татар язмышына караган мөһим тарихи вакыйгалар һәрчак булып торган. Беренчедән, шәһәр салынганда ук андагы сазлыкларда ятып калган кырык мең татар лашманын да онытырга ярамый. 1787 елда бирелдәге Фәннәр Академиясе басмаханәсендә, мөселманнар арасында түләүсез тарату өчен, Русия тарихында беренче мәртәбә Коръән мосхәфе нәшер ителә. Бу эш белән Госман мулла Исмәгыйлев җитәкчелегендә хәрби хезмәт үтәүче татарлар Хәмзә Мамышев[1], Гали Рәхмәтуллин[2] һәм Корбангали Исхаков[3] исемле татарлар шөгыльләнгән була. Госман мулла бу

[1] Хәмзә Мамышев (?–?) – беренче татар профессиональ хәреф җыючыларның (наборщикларның), Русиядә шәркый басма сәнгатенә нигез салучыларның берсе. 1799 елдан Санкт-Петербургтагы Фәннәр Академиясе матбагасында, 1800 елдан Казандагы «Азиатская типография»дә эшләгән. 1829 елда «Азиатская типография» Казан император университеты нәшриятына кушыла.

[2] Гали Рәхмәтуллин (1759–1834) – чыгышы белән Чистай ягыннан булган бу кеше 1780 елда рекрут буларак хәрби хезмәткә алына, Балтыйк диңгезендә, матрос булып, корабларда хезмәт итә, 1790–1791 елларда Русия белән Швеция арасындагы сугышта катнаша, ике медаль кавалеры. 1791 елның 25 декабрендә Екатерина II фәрманы белән Санкт-Петербургта Коръән бастыру белән шөгыльләнгән «Азиатская типография»гә хәреф җыючы (наборщик) буларак билгеләнә, 1880 елда Казанда ачылган «Азиатская типография»гә күчерелә.

[3] Корбангали Исхаков (1800 елдан соң вафат) – беренче татар профессиональ хәреф җыючыларының берсе. Көнчыгыш телләре белгече буларак, 1785 елда Екатерина II фәрманы белән хәрби хезмәттән алынып, Санкт-Петербургтагы «Азиатская типография»гә беркетелә һәм шунда 1800 елга кадәр Коръән бастыруга бәйле вазифалар башкара.

басма өчен киләчәктә мәшһүр «Казан басмасы»нда кулланылачак махсус гарәп шрифты ясаган була. Гомумән, 1798 елга кадәр Санкт-Петербургта Мосхәф биш мәртәбә нәшер ителә, шуннан соң гына 1801–1802 елларда Коръән гранкалары Казанга озатылып, Коръәннең «Казан басмалары» тарихы башлана. Шулай ук Санкт-Петербургта 1905 елда ахун Гатаулла Баязитов[1] тырышлыгы белән «Нур» исемле газета чыгарыла башлап, Русия күләмендә татар милли периодик матбугаты тарихын ачып җибәрә. Озак та үтми, шул ук 1905 елның 11 декабрендә С.-Петербургта казый Габдерәшит Ибраһим тарафыннан ачылган «Өлфәт» («Дуслык») газетасының беренче саны дөнья күрә, ә 1906 елның июль аенда аның «Әт-Тилмиз» («Шәкерт») исемле гарәп телле газетасы чыга башлый. Муса әфәнде искә алынган газеталарга мәкаләләр яза. 1905 елның 11 декабреннән 1907 елның 30 маена кадәр чыгып килгән «Өлфәт» газетасының 83 санында ул утызга якын мәкаләсен бастыра – аның иң беренче язмасы газетаның беренче санында чыккан булса, соңгысы 1906 елның 22 ноябрендәге санында чыга, ягъни 1907 елда Муса әфәнденең язмалары «Өлфәт»тә басылмый.

Русия мөселманнары хакына зур эшләр башлап алып барган Габдерәшит казыйның үзе, аның дини фикер үсешенә керткән өлеше, татар милли хәрәкәте тарихында тоткан урыны, Русия мөселманнарын мөстәкыйль сәяси көчкә әйләндерү өчен куйган көче-һиммәтләре һәм башка сөйләп-санап бетергесез каһарманлыклары турында аерым сөйләнергә тиеш. Мәсәлән, 1905–1906 елларда оештырылып, Русия мөселман-

[1] Гатаулла Баязитов (1847–1911) – чыгышы белән Касыйм татарларыннан булган күренекле дин һәм җәмәгать эшлеклесе, язучы, тарихчы, публицист, күпсанлы, шул исәптән рус телендә дә язылган китаплар авторы. Русиядә беренче «Нур» татар гәзитен оештыручы һәм нәшер итүче; Кышкар авылы (Татарстан, Арча районы) мәдрәсәсен тәмамлаган, 1871 елда Санкт-Петербургтагы мәчет имамы итеп сайлана, шул ук елдан башлап Тышкы эшләр министрлыгының Азия департаментында төрки телләр тәрҗемәчесе булып эшли башлый, шәрык телләре курсларында төрки телләр һәм фикъһы укыта. 1886 елда хәрби ахунд итеп билгеләнә.

нарын берләштергән «Иттифак-ы мөслимин» («Мөселманнар берлеге») исемле сәяси партияне барлыкка китерүдә нәкъ менә Габдерәшит казый хәлиткеч роль уйнаган. Китабыбыз Муса әфәндегә багышланганга күрә, Гомәр углы Габдерәшит хәзрәт Ибраһимовның татар милләте һәм, гомумән, ислам өммәте тарихында иң күренекле шәхесләрдән булуын әйтү белән чикләнәм дә, янәдән төп темага әйләнеп кайтам.

## Мөселман корылтайларында эшчәнлеге

Габдерәшит хәзрәт кебек могътәбәр вә тәҗрибәле зат белән иңне-иңгә терәп эшкә керешкән Муса Бигиев Русия мөселманнарының беренче сәяси съездларын әзерләүгә алына, аларның эшендә катнаша, шулай ук әлеге форумнарның документларын җыю һәм бастырып чыгару белән шөгыльләнә. Мәсәлән, 1905 елның август аенда Беренче Бөтенрусия мөселман корылтае үткәрелә. Аның эшендә катнашкан Муса әфәнде әлеге чараның документ һәм материалларын халыкка ирештерүне үз өстенә ала. Алга таба телгә алыначак «***Исляхат әсасләре***» исемле җыентыкта әлеге корылтай турында мәгълүмат «Тарихи мәҗлес» исемле бүлекчәдә китерелә[1]. Бу документ Русия мөселман җәмәгатьчелеге тарихында беренче олуг сәяси вакыйга турында кыска отчет рәвешендә Муса әфәнденең кулы белән язылганга күрә, аны китапның махсус кушымтасында тулысынча китердек[2]. Аны укып чыккан һәркемгә аңлашылачак ки, Русия мөселманнарының Беренче корылтаеның беренчелеге сан исәбе белән чикләнми. Биредә сөнниләр белән шигыйлар ислам тарихында беренче мәртәбә бер-берсенә сәлам биреп, иңгә-иң терәп эшкә тотынганнар. Бу җәһәттән, Русия мөселман корылтайлары әле хәзерге вакытта да үзара килешә алмаган бу ике дини агым вәкилләре өчен менә дигән үрнәк булып тора.

Муса әфәнденең корылтай эшчәнлегендә катнашуы аның документларын туплау, бастыру, чараны матбугатта яктырту

---

[1] Исляхат әсасләре. Төз. Муса Җаруллаһ. Петроград: Тип. М-А. Максутова, 1915. Б. 169–175.

[2] Карагыз: III Бүлек. 1: Тарихи мәҗлес.

белән тәмамланмый. Галимҗан Ибраһимов[1], Габдулла Апанаев[2] кебек могътәбәр шәхесләр белән бергә, Муса әфәнде әлеге корылтайда тәгаен кылынган дүрт эшлекле группаның берсе булган ислам исляхчылары һәм миссионерлыкка каршылык күрсәтү төркеменең әгъзасы итеп билгеләнә.

1906 елның язында Али-Мәрдан Тупчибашев[3] тарафыннан әзерләнеп, I нче һәм II нче Бөтенрусия мөселманнары корылтайларының карарнамәләрен һәм «Иттифак әл-мөслимин» партиясенең уставын үз эченә алган махсус җыентыкка Муса әфәнде кереш сүз яза. Алга таба ул, мөселман корылтайларының документларын туплап, тагын берничә җыентык бастыра: «***Русия мөселманнары иттифакының програмы***» (Спб., 1906); «***1906 сәнә 16–21 августда иҗтимаг итмеш Русия мөселманларының нәдвәсе***» (Казан, 1906); «***Русия мөселманнарының Өченче нәдвәсе***» (Казан, 1906); «***Русия мөселманнарының Өченче нәдвәсенең забыт җәридәләре***» (Казан, 1906); «***Нижний Новгородта вакыйг улан Русия мөселманлары өченче нәдвәсенең мокарраралы (16–21 август, 1906)***» (Казан, 1906).

[1] Галимҗан Ибраһимов (Гыйрфан углы Галимҗан Ибраһимов; 1887–1938) – язучы, тел галиме, җәмәгать эшлеклесе, совет татар әдәбиятына нигез салучыларны берсе. Хезмәт герое (1932). «Солтангалиевчылар» процессы буенча кулга алына һәм үлем җәзасына хөкем ителә. 1955 елда реабилитацияләнә.

[2] Габдулла Апанаев (Габделкәрим углы Габдулла Апанай; 1962–1919) – дин галиме, мөдәррис, дин һәм җәмәгать эшлеклесе, публицист; 1902–1906 елларда «Казан шәһәренең ярлы мөселманнарына иганә җәмгыяте»н җитәкли. Аның эшен тәртипкә салып мохтаҗларга күп файда китерә. 1908–1910 елларда Вологдада сөргендә. 1917 елдан Казан губернасы мөхтәсибе, Идел-Урал штаты тарафдары. Большевик инкыйлабына каршы чыга, 1919 елда алар тарафыннан кулга алына һәм М. Вахитовны үтерүне әзерләүдә гаепләнеп атып үтерелә.

[3] Али-Мәрдан Тупчибашев (Әләкбәр углы Алимардан-бек Топчибашев; 1863–1934) – азәрбәйҗан җәмәгать һәм дәүләт эшлеклесе, юрист, журналист; Беренче Дәүләт думасы депутаты (1906), 1918–1920 елларда Азәрбәйҗан Демократик Җөмһүрияте хөкүмәтенең рәисе.

«***1906 сәнә 16–21 августда иҗтимаг итмеш Русия мөселманларының нәдвәсе***» исемле җыентыкта Муса әфәнде репортаж рәвешендә язган «*Гомум Русия мөселманларының рәсми өченче мәҗлесләре*» исемле документка игътибар итик: «*«Өлфәт» мөхәррире Габдерәшит әфәнде Ибраһимовның тырышлыгы вә иҗтиһады белән Нижний Новгородта Макарья базары тышында Русия мөселманнарының гомуми җыелышларына Эчке эшләр нәзараты тарафыннан рәсми рөхсәт 1906 елның 11 августында бирелгән иде. Рөхсәт турындагы хәбәр һәр тарафка телеграмнар белән игълан ителде. Кавказ, Кырым, Төркестан, Сибирия, [Русиянең] эчке вилаятьләреннән җыен үткәрелүен өмет итеп бик күп вәкилләр килгән иде. Корылтай мәҗлесләре биш көн дәвам итте…*

*…Рәшид әфәнде ачылыш хотбәсен укый башлады. Хотбә шул мәгънәдә иде:*

*«Әл-хәмде ли-ллаһи галә дини-л-ислам*[1]*! Әй мөселманнар! Безләр, – җөмләмез, – әлхәмде лиллаһи, һәм дә янә, әлхәмде лиллаһи – карендәшләрмез: безне ислам дине беребезне башкабызга карендәш итмештер.*

*Карендәшләр! Дикъкать итеңез: сәясәт исламиянең иң беренче адымы карендәшлек иттихады*[2] *иде. Хәзрәт нәби әкрам, саллә Аллаһу галәйһи вә сәлләм, әүвәлән ислам диненә Мәккә Мөкәррамәдә дәгъвәт итте; һәрҗирдә вәгазь сөйләп гыйлемләндерү белән мәшгуль иде. Хәзрәт пәйгамбәрнең Мәккә Мөкәррамәдә сәяси бер адымы яки хәрәкәте күренмәде.*

*Әхвәлнең басымы белән, Ходай хәзрәтләренең әмере белән хәзрәт нәби әкрам, саллә Аллаһу галәйһи вә сәлләм, Мәккәдән Мәдинәгә һиҗрәт итте. Иң әүвәл кулланган асыл сәясәте шул иде ки, Мәдинә Мөнәүвәрәдә булган әнсар белән Мәккә Мөкәррамәдән килгән мөһаҗирләр арасында карендәшлек килешүе төзеде.*

*Әнсар, ягъни Мәдинәнең җирле халыклары малларын, җирләрен бүлгәләп Мәккәдән килгән мөһаҗирләр фокарасы-*

---

[1] Әл-хәмде ли-ллаһи галә дини-л-ислам – Ислам дине өчен Аллаһка мактаулар.

[2] иттихад – бердәмлек.

*на бирер иделәр; ике хатыны булган әнсарлар берсен талак итеп, хатынсыз моһаҗиргә бирер иделәр.*

*Акылны эшкә җигеп аз гына уйласак, нәби әкрамның, әсхаб кирамның*[1] *шул хәлләренә игътибар белән карасак, күрербез ки, иттихад безнең динемезнең иң асыл сәясәтедер; карендәшлек иң нык нигезедер…*»[2].

Әлеге язмада, беренчедән, Муса әфәнденең корылтайның ачылыш сүзен хотбә дип атавы игътибарны җәлеп итә. Безгә таныш булган мәгънәдә хотбә бәйрәм намазлары алдыннан имам-хатыйплар тарафыннан җыелган мөселманнар алдында укыла торган вәгазь буларак кабул ителә. Ягъни саф дини бер йола. Әмма Муса әфәнде хотбәнең өммәтнең яшәешенә, вазгыятенә кагыгылышы булган теләсә нинди темага – сәясәт булсын, икътисад булсын, иҗтимагый мәсьәләләр булсын, әдәп-әхлак мәсьәләләре булсын – багышлана алуын ассызыклый. Ягъни хотбә тормыштан аерылып, йола гына булып калырга тиеш түгел. Икенчедән, Муса әфәнде карендәшлекнең, ягъни иман ияләренең үзара бертуганнар булуларын ислам диненең куәт вә гыйззәтен тәэмин итә торган сыйфат дип күрсәтә. Бу фикер инде беренче Корылтайда ук әйтелгән генә түгел, хәтта гамәлгә ашкан була – сөнниләр белән шигыйларның сәламләшеп бергә эшләүләрен искә төшерик. Бердәмлек идеясе галимнең һәр китабында диярлек ярылып ята, ягъни, исламиятнең хәерле-гыйззәтле киләчәге турында сүз йөрткәндә ул аны, беренче нәүбәттә, мөселманнарның бердәм булуларына баглаган.

Инде «***Нижний Новгородта вакыйг улан Русия мөселманлары өченче нәдвәсенең мокаррараты (16–21 август, 1906)»*** җыентыгында китерелгән мәгълүматка игътибар итик. Аның 19–20 нче сәхифәләрендә яшерен тавыш бирү рәвешендә үткәрелгән сайлау нәтиҗәсендә Муса әфәнденең унбиш шәхестән торган Үзәк идарә әгъзасы буларак сайланылуы турында хәбәр бар: ««*Гайн(е)*[3] *мәҗлесдә (20–21 август)*

[1] әсхабе кирам – игелекле сәхабәләр, ягъни Мөхәммәт пәйгамбәрнең вәгазен танып, ислам динен кабул иткән замандашлары.

[2] Документ татар теленә тәрҗемә ителеп бирелде.

[3] Гайне – шул ук.

*раъйе хәфи*[1] *ысулыйлә, идарә-и мәркәзия әгъзасы интихаб улындыгы*[2] *иң чук раъйи*[3] *казанмак сырасыйлә*[4] *шунлардыр*:

*(...) 9) Шаһ Хәйдәр әфәнде Сыртланов, земства адәмләрендән вә сабикъ*[5] *Дума әгъзасындан.*

*10) Муса әфәнде Бигиев, «Өлфәт», «Тилмиз» газитәләренең мөхәррирләрендән, Петербург дарелфөнүне сәрбәст*[6] *таләбәсендән.*

*11) Габдулла әфәнде Буби, мөгаллиминдән*[7].

*12) Һади әфәнде Максуди, «Йолдыз» мәҗмугасы мөхәррир вә нашире...»*.

«*Иң чук раъйи казанмак сырасыйлә*» дигән гыйбарә хәзерге телдә «иң күп тавыш казану тәртибе белән» булып яңгырый. Димәк, Русия мөселманнарының йөзек кашы дәрәҗәсендәге кешеләр арасыннан иң лаеклылары үз файдаларына никадәр тавыш бирелүенә күрә сайланылганнар. Китерелгән өземтәдән күренгәнчә, Русиягә нибары ике ел гына әүвәл кайткан Муса әфәнденең абруе шул кыска вакыт эчендә аның мөселманнарның сәяси һәм иҗтимагый активлыклары белән идарә итәчәк әлеге югары органга сайланылуын мөмкин итәрлек дәрәҗәдә югарылыкка күтәрелеп өлгергән булган.

Муса әфәнденең «Өлфәт»тә чыккан публицистикасында мөселман корылтайларының эшчәнлеге, Петербург мөселманнарының иҗтимагый тормышындагы вакыйгалар, дини уку-укыту мәсьәләләре, ислам тарихы һәм башка темалар яктыртыла. Бу елларда Муса әфәнде Казанда чыгып килгән «әл-Ислах»[8] гәзите һәм Уральск каласында чыккан «әл-Гасыр

---

[1] раъйе хәфи – яшерен тавыш бирү.

[2] интихаб улындыгы – сайланылганы.

[3] иң чук раъйи – иң күп тавышны.

[4] сырасыйлә – нәүбәте белән, тәртибе белән.

[5] сабикъ – үткәндәге; әүвәлге, элекке.

[6] сәрбәст – ирекле, үз иркендә булган.

[7] мөгаллиминдән – мөгаллимнәрдән, укытучылардан.

[8] «әл-Ислах» – 1907–1909 елларда Казанда нәшер ителгән татар милли-демократик газетасы. Гәзиттә баш рольләрне Габдулла Тукай белән Фатих Әмирхан уйныйлар.

әл-җәдид»[1] журналында да мәкаләләр бастыра. Муса әфәнденең үз китапларын татар теленең госманлы шивәсендә яза башлавының сәбәбе дә, минемчә, аның Габдерәшит казый Ибраһим белән хезмәттәшлек итүендә, олпат затның Муса әфәндегә тәэсир итүендә булса кирәк.

***

Муса әфәнде 1905–1907 елларны үз эченә алган дәвердә сәясәт дөньясында үзен берникадәр танытса да, ул, шулай да, чәчрәп йөрмәгән, күренекле шәхесләребез арасында үзен тыйнак тоткан, күбрәк корылтайлар белән бәйле булган беркетмәләр язу, протоколлар алып бару, аларны бастыру эшләре белән шөгыльләнгән. Болай караганда аның татар сәяси олимпының күренекле эшлеклеләре арасында урын алырга омтылмаган булуы сизелер. Һәм бу нигезсез дә түгел: Муса әфәндене шәхсән белгән Габдулла Баттал-Таймас[2] Муса Бигиевкә багышлаган бер китабында болай дигән: «*Русиягә кайтканыннан соң узып киткән 7–8 ел дәвамында мөселман корылтайларында башкарган сәркятип вазифаларын исәпкә алмаганда, ул үз өстенә җаваплы иҗтимагый вазифалар йөкләүдән читләшә иде*»[3].

Югарыда язылганнарга ачыклама рәвешендә, Муса әфәнденең үз кулы белән үтенеч сурәтендә язылган бер документ китерәсем килә. Анда аның киеренке елларда үзен ничек хис итүе, милләт олылары арасында үзенең урынын нинди итеп

---

[1] «әл-Гасыр әл-җәдид» –1906–1907 елларда Җаек шәһәрендә чыккан әдәби-сәяси журнал. Нашире һәм рәсми мөхәррире Камил Мотыйгый булган, журналның актив язучысы буларак, Габдулла Тукай аның сәхифәләрендә үзенең беренче әсәрләрен бастырган.

[2] Баттал (Габдел-Барый Баттал Таймас; 1880/83–1969) – татар журналисты, педагог, тарихчы, мәгърифәтче, лексикограф, XX йөздә чыккан беренче татар тарихы дәреслеге авторы. СССРдан качканнан соң, башта Финляндиядә яши, аннары Төркиягә күчеп китә. 1958 елда Истанбулда «Musa Carullah Bigi. Kişiliği, fikir hayatı ve eserleri» исемле биографик китабын бастыра.

[3] Battal-Taymas, A. Musa Carullah Bigi. Kişiliği, fikir hayatı ve eserleri. Kazanlı Türk Meşhurlarından II. İstanbul, 1958. S. 14.

күрүе, ул олпат затлар арасында нинди эш башкарган булуы яхшы күренә: «*1906 сәнә август 16-дан август 20-гә кадәр биш көн дәвам иткән мәҗлесләр Русия мөселманнары өчен беренче мәртәбә үткәрелгән рәсми гомуми милли мәҗлесләр иде. Бу мәҗлесләрдә җыелыш үткәрү әдәбе җиренә җиткерелеп, фикер алышу мәйданына куелган мәсьәләләр Русия мөселманнары өчен иң мөһим мәсьәләләр иде. Иң беренче гомуми җыелышта хатыйбларыбыз тарафыннан күрсәтелгән осталык безнең киләчәгебезгә зур бер бәшарәт*[1] *иде.*

*Мондый гадәттән тыш зур бер милли мәҗлестә үткәргән сәгатьләремне гомеремнең иң кадерле дакыйкаларыннан*[2] *исәпләп, корылтай тарафыннан йөкләнгән мөстәшарлык*[3] *вазифасын тәмам тырышлык белән үтәп бардым.*

*Бу биш көн дәвамында мин башка нәрсәләрдән тулысынча аерылып, һушымны һәм гүшемне*[4] *хатыйблар хотбәсенә, сөйләнгән сүзләргә төбәгән идем.*

*Стенограф булмадыгыннан хотбәләрнең сүзләрен ничек бар – шулай тәмамына кадәр теркәп бара алмасам да, кулым каләмдә, гүшем хатыйбның авызында, һушым башка нәрсәләрдән тәмам аерылганыннан, һәр хатыйбның асыл фикерләрен теркәп барырга иҗтиһад итә идем.*

*Соңрак Идарә мәркәзия әгъзаларының әмере белән үзем теләп, мин Казанга килеп забыт җәридәсен*[5] *язарга, «милләтнең фикерләрен дә милләткә җиткерергә» алындым. Уртача исәпләгәндә мин һәр көн 8 сәгать эшләп, матбаганың ярдәме белән бер ай эчендә забыт җәридәсен тәмам иттем.*

*Забыт җәридәсен язганда, мин хатыйб әфәнделәрнең үз гыйбарәләрен язып барырга тырышсам да, еш кына фикерләрен бәйан итүгә күчеп, үз гыйбарәләрем белән яза идем.*

[1] бәшарәт – сөенче, шатлык хәбәре.

[2] дакыйка – минут.

[3] мөстәшар – киңәшче, референт.

[4] һушымны һәм гүшемне – акылымны һәм колагымны.

[5] забыт җәридәсе – протокол.

*Мин белә торып һичбер фикернең нигезенә каршы булган нәрсәләр язмадым. Ике хасымның*[1] *беренә тәгассыб*[2] *итеп, башкасының сүзен раунаксыз*[3] *бәян итүдән бөтен куәтем белән читләшә итдем.*

*Инкяр итмәм, шик юк, мин хатыйбның сүзен тыңлаганда аңламау ихтималым бар, забыт җәридәсен язганда әледән-әле ялгышу ихтималым бар.*

*Ләкин мин ни ул хәлдә, ни бу хәлдә гамьсезлек-игътибарсызлык кыйлмадым, һәр ике хәлдә тәкатем җиткән кадәр игътибарлы булдым. Мин, һәрхәлдә, максатка тулысынча ирешмәсәм дә, булдырган кадәр көчемне багышладым.*

*Бу нәрсәләрне тәкъдим итеп, хатыйб әфәнделәрдән үтенәм ки, хотбәләрен язганда барлыкка килгән кимчелекләрне минем кебекләрдән табигый бер нәрсә дип белеп, моннан соң милләт балаларыннан стенография сәнәгатен белә торган адәмнәр әзер итсеннәр.*

*Казан, 1324 сәнә 28 шәгъбан*
*Чәһаршәнбә, 1906 сәнә 4* октябрь.
*Муса Бигиев*»[4].

Әлеге документтан аңлашылганча, татар милли хәрәкәте тарихының беренче сәхифәләре нәкъ менә Муса әфәнденең кулы белән кәгазьгә теркәлеп барган һәм аның эшкәртүендә басма материал хәлендә дөнья күргән. Бу нисбәттә генә дә аның татар тарихына, Русия мөселманнарының сәяси хәрәкәте һәм иҗтимагый фикере тарихына керткән өлеше бәһасез.

Муса әфәнденең сәясәт мәйданында чәчрәп йөрмәвен аңа хас тыйнаклык белән аңлатып булыр иде, әмма мәсьәлә, чынлыкта, улкадәр үк гади түгел. Беренчедән, никадәр тыйнак булса да, Муса әфәнде 1906 елның 16–21 августында үткәрелгән Бөтенрусия мөселман корылтаенда оештырылган «Иттифак-ы мөслимин» фиркасенең унбиш кешедән торган

[1] хасым – кара-каршы торучы; оппонент.

[2] тәгассыб – хушлану, фанатикларча иярү.

[3] раунак – купшылык; ялтыравык; матурлык.

[4] Документ татар теленә тәрҗемә ителеп бирелде.

идарәсенә сайланыла. Димәк, олпат дин кардәшләре аңа тиешле бәя бирә белгәннәр. Икенчедән, Муса әфәнденең сәяси эшчәнлек даирәсендәге бер үзенчәлегенә игътибар иттерәсем килә: аның тыйнаклыгы эшнең ислам диненә бәйле булган теге яки бу мәсьәләгә кагылуына кадәр генә җиткән. Дин турында сүз чыктымы, Муса әфәнде бер арысланга әйләнә торган булган, һичкемнән курыкмыйча иҗтимагый мәйданга иң киеренке рухи һәм дин гыйлемнәренә караган проблемаларны чыгарган, бәхәсле темалар кузгаткан, мөселман чынбарлыгының никадәр мескен һәм аяныч булуын фаш иткән, кыскасы – үзенең асыл мәсләгенең сәясәт, сәяси эшчәнлек түгел, ә нәкъ менә дин һәм дингә кагылышлы барлык нәрсәләр белән бәйле булуын ачык күрсәткән. Димәк, дини сәясәтне, диннең сәясәттән аерылыгысыз булуын күздә тотканда, Муса әфәнде сәясәтнең мондый төреннән һич тә читләшмәгән, киресенчә, мәсьәләнең үзәгендә кайнаган. Бу җәһәттән, Муса әфәндене, һич тә тартынмыйча, олуг дини сәясәтче дип атарга була. Бу дәгъваны раслар өчен Муса әфәнденең бөтендөнья мөселманнарына кагылышлы ислам конституциясе дәрәҗәсендә булган бер җитди сәяси хезмәт язган булуын искә алу җитә. Аның бу әсәре, 1917 ел Февраль демократик инкыйлабының Муса Бигиевнең иҗтимагый-сәяси эшчәнлегендә яңа этап башлап җибәрүе, һәм, гомумән, аның дин сәясәтчесе яки диндар сәясәтче буларак кылган хезмәтләре һәм бәян иткән фикерләре турында сүзебез алда әле.

### Казан: 1907–1909 еллар. Яңа китаплары. Әхмәт-Зәки Вәлиди

Басмага әзер булган бер китабын бастыру нияте белән Муса Җаруллаһ 1907 елда Казанга килеп төшә һәм «әл-Ислах» гәзите редакциясе урнашкан йортның өске катында бүлмә яллап тора башлый. Казанда ул 1909 елның, кимендә, беренче айларына кадәр яшәп ала. Галимнең Казанда үткәргән вакыты нәтиҗәле була: 1907 елда гына да ул өч китабын бастырып чыгара.

Ул өч китапның беренчесе – Казанда һиҗри ел исәбе белән 1325 елда чыккан «***Китабу әш-Шатыбийәти***»[1]. Бу Муса әфәнденең югарыда «басмага әзер булган бер китабы» дип телгә алынган хезмәте булса кирәк. Гарәп шигъри үлчәмнәренең берсе белән язылган бу борынгы әсәр Бигиевнеке түгел – аны милади 1144–1194 елларда гомер иткән күренекле Коръән белгече Әбу Мөхәммәд (шулай ук Әбу әл-Касим) әл-Касим ибне Фиррах ибне Халәф ибне Әхмәд әр-Роәйни аш-Шатыйби хәзрәтләре язган. Әмма Муса әфәнде бу хезмәтнең Русия мөселманнары арасында чын мәгънәдә Коръән гыйлемен тарату һәм тирәнәйтү өчен үтә дә әһәмиятле булуын яхшы күзаллаганга күрә, аны бастырып таратуны кирәкле эш дип таба. «***Китабу әш-Шатыбийәти***» гарәп телендә язылып, бер яктан Коръән кыйраәтләренә, ягъни укылышларына багышланган җитди гыйльми хезмәт буларак игътибарга лаек булса, икенче яктан үзенең шигъри калыпка салынып *касыйдә* жанрында язылган булуы белән шаккаттыра[2]. Бу үзенчәлек әлеге әсәрне аңлауны һәм аннан файдалануны, әлбәттә, кыенлаштыра гына түгел, бәлки мөмкинлек даирәсеннән чыгара, чөнки гарәп телен белмәүчеләр өчен ул бөтенләй йозак астындагы бер хәзинә булса, гарәп телен белгән теләсә кем дә аны аңлый алмаячак: бу очракта гарәп телен белү генә җитми, гарәп шигърияте дә, образлар байлыгын да, шигъри тел үзенчәлекләрен дә тирәнтен белергә кирәк. Бу нисбәттән, безгә китапның бары тик кереш сүзе белән танышырга кала. Анысын Муса әфәнде госманлы-татар телендә язган, гәрчә

[1] «Китабу әш-Шатыбийәти», яки «Шатыбийә» – китапның тулы исеме: Китабу әш-Шатыбийәти ли-имами әл-хуффаз әл-әгълам әл-устаз Аби Мүхәммәд әл-Касим әш-Шатыби радыя Аллаһу ганһу. Казан: Лито-Типография Торговаго Дома «Братья Каримовы», 1907. 88 б.

[2] касыйдә – Шәрык мөселман халыкларында таралыш тапкан шигърият жанры. Касыйдә катгый кагыйдәләргә туры килергә тиеш, мәсәлән, бәетләр саны никадәр булса да, аның һәр бәете гел бер хәрефкә тәмамлана. Телгә алынган «Китабу әш-Шатыбийәти»дәге касыйдәнең 900 бәетенең һәммәсе ахырында ләм-әлиф (لا) хәрефләре торган сүзләр белән тәмамлана.

исемен гарәпчә куйган булса да – ул мәкалә «***әл-Әхруфу әл-Куръәнийә вә таъриху әл-кыйраъәти***» («*Коръән укылышы төрләре һәм кыйраәт тарихы*») дип атала. Бу мәкалә аерым рисалә буларак та, «***Китабу әш-Шатыбийәти***» белән бер том эчендә дә басылып чыга[1].

Нибары 17 сәхифәлек әлеге чыганак мөстәкыйль гыйльми хезмәт буларак кабул ителергә тиеш. Кереш сүздә «***Китабу әш-Шатыбийәти***»нең ифрат та кыйммәтле әсәр булуын бәян иткәндә Муса әфәнде мондый сүзләр язган:

«*Мин шундый уйларга таянып, Коръән гыйлеме дәресләрен ислах кыйлу юлында бер адым булыр дигән өмет белән, бу юлы Кәримов хәзрәтләренең[2] тырышлыгы белән «Шатыбийә»не нәшер иттем. Чөнки Коръән өчен дә, борынгы калыпта язылган тәфсирләрне укыр өчен дә «Шатыбийә»не белү зарурдыр. Һәм дә бу фәндә «Шатыбийә» кебек файдалы һәм җиренә җиткерелеп язылган китапны табып булмый һәм табып булмаячак та*»[3].

Бу әсәрдән тагын бер өзек китерик: «*Безнең Русиядәге дини мәдрәсәләрдә Коръән гыйлемнәренә таяну гаять зәгыйфь: нәху[4], сарыф[5], бәлягать[6] кебек Коръәннең бары тик гарәбилегенә[7] кагылышлы гыйлемнәр берникадәр укытыл-*

---

[1] Бу чыганакны кара: https://darul-kutub.com/books/1331/

[2] Кәримов хәзрәтләре – бертуган Кәримовларның (Шәрифҗан, Мөхәммәтҗан, Хәсән) Казандагы «Мәтбага-и Кәримия» исеме белән дан казанган мәшһүр басмаханәләре (1900–1918) күздә тотыла. 1901–1917 елларда әлеге нәшриятта 19 647 076 тираж белән 1 700 исемдә татар китабы бастырыла.

[3] Хәзерге татар теленә тәрҗемә, монда һәм алга таба, башка мөтәрҗиме күрсәтелмәгәндә, безнеке.

[4] нәху – җөмлә төзелеше; синтаксис.

[5] сарыф – сүзләр төрләнеше, морфология; грамматика.

[6] бәлягать – сөйләм һәм язма телнең матурлыгы, төзеклелеге, бәян ителәсе фикерне җиткерүдә камиллеге.

[7] гарәбилек – әлеге сүзнең мәгънәсен Коръәннең асыл теле булган гарәп теленең грамматикасы, синтаксисы, кагыйдәләре, нечкәлекләре һәм гарәпләргә хас булган яшәү рәвешенең Коръәндә чагылыш тапкан кайбер үзенчәлекләре, гореф-гадәтләре тәшкил итә.

*са да, Коръәннең «кеше тормышында бер гадел канун, аның киләчәктә бәхеткә ирештерәчәк бер рәһбәр[1]» булуына караган гыйлемнәр бөтенләй укытылмый. Бу да сәбәбе күренеп торган бер нәрсә: чөнки табигать фәннәре, фәлсәфә, сәясәт, икътисад, тарих кебек гыйлемнәрне өйрәнмәгән бер милләт, әлбәттә, Коръәннең искә алынган ягына игътибар биргән милләт була алмаячак*»[2].

Муса әфәнде 1907 елда чыгарган икенче китап «***әл-Лүзүмийәт***» исеме белән танылган булса да, аның тулы исеме күпкә озынрак: «***Фәйләсүф имам кәбир Аби әл-Галә әл-Мәгарри хәзрәтләренең әл-Лүзүмийәт намында бөек әсәрендән интихабән бер биң өч йөз кадәр әдәбийат гыйльмийә тәрҗемә улынды Муса Бигиеф каләмейлә***»[3].

Муса әфәнде бу хезмәтен шулай ук «***Шәрху әл-Лүзүмийәти***» («*Лөзүмиятнең аңлатмасы*») дип тә атый. Әлеге хезмәтнең эчтәлеге, жанры, филологик үзенчәлекләре генә түгел, дөньяга килүе тарихы да кызыклы: Казанда Муса әфәнде очраклы рәвештә «Шәрык» көтебханәсенең хуҗасы, күренекле нашир Әхмәд әфәнде әл-Исхакый[4] белән таныша. Берничә мәртәбә күрешеп сөйләшкәннән соң, нашир Муса әфәндегә: «*«Лөзүмийәт»тән өлешләр сайлап алып тәрҗемә ит. Мин нәшер итәрмен; шәкертләр файдаланырлар. Бу хезмәтнең сиңа да, миңа да, милләтебез шәкертләренә дә файдасы булыр. Мөсаһәлә итмә[5], ике-өч ай дәвамында тәмам кыйл!*» дип киңәшен бирә.

Гаҗәп, әмма иҗади планнарында каралмаган бу эшне Муса әфәнде вакытында тәмамлый, һәм Әхмәт әфәнде аны бастырып чыгара. Күләме шактый зур булган бу китап асыл «әл-

---

[1] рәһбәр – әйдәүче, әйдәп баручы; юлбашчы.

[2] Өзек татар теленә тәрҗемә итеп бирелде.

[3] Фәйләсүф имам кәбир Аби әл-Галә әл-Мәгарри хәзрәтләренең әл-Лүзүмийәт намында бөек әсәрендән интихабән бер биң өч йөз кадәр әдәбийат гыйльмийә тәрҗемә улынды Муса Бигиеф каләмейлә. Казан: Әхмәд әл-Исхакый нәшрияты, 1907. 208 б.

[4] Әхмәд әл-Исхакый (?–?) – күренекле татар нашире, матбагачы.

[5] мөсаһәлә итмә – җиңелгә алма (руз игътибар һәм тырышлык белән җиренә җиткерелеп эшләнергә тиешле бер эшкә карата).

Лөзүмийәт»тән сайлап алынган парчаларны үз эченә ала һәм өч кисәктән гыйбарәт була: 1) Муса әфәнденең кыска гына кереш сүзе; 2) Әбу әл-Галә әл-Мәгарринең[1] 50 сәхифә дәвамында сурәтләнгән биографиясе һәм дини-фәлсәфи карашлары; 3) әл-Мәгарриның «әл-Лүзүмийәтү»[2] исемле фәлсәфи поэмасыннан сайлап алынып тәрҗемә ителгән парчалар. Һәр шундый парча әл-Мәгарринең гарәп телендә язылган шигъри икеюллыкларны, аларның госманлы татар теленә тәрҗемәсен һәм тәрҗемәченең, ягъни Муса әфәнденең аңлатма-шәрехләрен үз эченә ала.

Мисал өчен, тәрҗемәнең шундый бер кисәген карыйк. Башта җәя эчендә Әл-Мәгарри хәзрәтләре язган бәетләрнең гарәпчәсе китерелә:

(وما ادب الاقوام فى كل بلدة * الى المين الا معشر ادباء)

түбәндәрәк асыл бәетнең тәрҗемәсе һәм шәрехе, ягъни аңлатмасы килә:

«*Адәмләри батыйль вә заляля ялңыз галимләр вә фәкыйһлар дәгъвәт итде.*

*Шу мәсьәлә уйлә вазыйх бер хакыйкатьдер ки ийзах истәмәз: миләл сәмавия тәварихына бер назар идәр исәк, тәгалим илаһияйә тари улан инхирафи күрүр исәк, руй-е арызда табакат-е наснең әхваль икътисадия вә сәясиясенә игътибар күзе салур исәк имамның шу бөек сүзене тасдыйк идәрез*».

Парчаның хәзерге телгә тәрҗемәсе:

«*Адәмнәрне ялган вә адашуга бары тик галимнәр вә фәкыйһлар чакырды.*

---

[1] Әбу әл-Галә әл-Мәгарри (973–1057/58) – гарәп шагыйре, тел белгече һәм зөһед фәлсәфәче; тумыштан сукыр була, заһидләрчә (аскетларча) тормыш итә; акылның иманнан югары торуын дәгъвалаган ирекле фикер тарафдары була, тәкъвалыкка яман гамәлләр кылмау аша ирешергә чакыра. Аллаһның берлеген таныган тәүхид иясе булса да, диннәрне танымаган, дини тәгълимат исеме белән кешеләрнең акылларын бутауга, шул рәвешле томана итүләренә каршы чыккан.

[2] Әсәрнең тулы исеме «Лүзүмийәтү мә ләм йәлзәм», ягъни «Кирәксезнең кирәклеге».

*Бу мәсьәлә шундый ачык бер хакыйкать ки, ачыклама таләп итми: күктән иңгән диннәр тотучы милләтләрнең тарихларына бер караш салсак, илаһилек белемен юлдан яздырган бозыклыкны күрсәк, җир йөзендә кешеләр катламнарының икътисади вә сәяси хәлләренә игътибар күзе салсак, имамның бу бөек сүзенең дөрес булуын таныр*быз».

Муса әфәнденең бу хезмәте ул чорның гыйлемгә омтылган татар шәкертләренә һәм зыялыларына зур тәэсир ясый. Мәсәлән, Әхмәт-Зәки Вәлидинең әйтүенә караганда, Муса әфәнденең бу әсәрен уку аркасында аның гарәп шигърияте яратуы нык көчәя һәм бу яратуны ул гомере дәвамында күңел түрендә саклый. Гомумән алганда, әлеге «әл-Лүзүмийәт» тәрҗемәсе аңа хас булган тирән дини-әхлакый-фәлсәфи эчтәлеге, әдәби-нәфис үзенчәлекләре белән генә түгел, татар теленә гарәп теленнән ясалган кайтарма үрнәге буларак та өйрәнелергә лаеклы. Татар язма сүзе һәм иҗтимагый фикер тарихының әлегә кадәр өйрәнелмәгән хәлдә яшеренеп яткан бәһасез бер җәүһәре булганга күрә, ул, әлбәттә, халыкка кайтарылырга тиеш.

Шул ук 1907 елда Муса әфәнде Казанда үзенең «***Әдәбийат гарәбийә илә голүм исламийә***»[1] («Гарәп әдәбияты һәм ислами гыйлемнәр») исемле өченче китабын бастыра. Үзе әйтүенчә, ул «*Әл-Лүзүмийәт*» тәрҗемәсенә бер өстәмә рәвешендә язылган. Бу хезмәт Муса әфәнденең госманлы-татар телендә язылган беренче оригиналь әсәре булып, автор, беренче нәүбәттә, гарәпчә язылып мәдрәсәләрдә уку-укыту процессында кулланылган китапларга кискен тәнкыйди бәяләмә бирә, гарәп әдәбияты төшенчәсенең ни икәнлеген аңлатып аңа фәнни билгеләмә тәкъдим итә, гарәп телле әсәрләрне тәрҗемә итүнең теоретик һәм гамәли проблемалары турында сүз йөртә, шулай ук үтә дә киеренке гомумфәлсәфи, иҗтимагый, дини һәм рухи мәсьәләләр куя. Муса әфәнденең «*Аллаһның берлеген дәлилләү, барлыгын исбат итү мәсьәлә-*

---

[1] Муса Бигиев. Әдәбийат гарәбийә илә голүм исламийә. Казан: «Мәгариф», 1909. 72 б.

*ренә багышланган «Рисалә-и исбат-ы важиб әл-вөҗүд»*[1] *кебек файдасыз нәрсәләрне мәдрәсә шәкертләренә укытып, бичара шәкертләрнең йөрәкләрендә булган иман нурын бөтенләй юкка чыгара идек*» дигән сүзләре генә ни тора! Ул алар урынына күпмилләтле мөселман даһилары тарафыннан гарәп телендә иҗат ителеп, адәм баласын рухландыруга, фикри үсешен тәэмин итүгә, дөньяга карашын киңәйтүгә, аның чын мәгънәдә иманлы, тәвәккәл һәм эшлекле заман кешесе булып җитешүенә хезмәт итә алырлык бихисап борынгы әдәби ядкәрләрне кулланылышка кертергә тәкъдим итә. «*Әдәбийат гарәбийә...*»дә Муса әфәнденең мондый сүзләре бар: «*Гарәп тел белеме ияләренең хезмәтләре миңа тагын да гаҗәп, тагын да шаккатыргыч булып күренде: башта мин гарәп телендәге әдәбият бары тик файдасыз, буш, кирәксез нәрсәләрдән гыйбарәт матур сөйләм сәнгатенә хезмәт итә торган бер нәрсә дип уйлый идем. Гарәп шигърияте бары тик хәерчелек аркасында әмирләрне мактап иҗат ителгән назымнан, яки бер мәхбүбнең йөзенә-күзенә, буй-сынына сокланудан сөйләнгән саташуларыннан гыйбарәт дип уйлый идем. Ләкин хакыйкать алай түгел икән! Гарәп телендә иҗат ителгән шигырьләрне аз булса да укыдым. Җаһилият чоры гарәпләренең табигатьне тасвирлау осталыгын күреп, гарәп шигърияте хакында фикерем кинәт үзгәрде: хөррият, кыюлык, тырышлык, тугрылык, чаманы белеп, сакланып эш итү, галиҗәнаплек, батырлык, ихтыяр көче, киң күңеллелек, юмартлык, гыйффәт һәм сафлык, намуслылык, ышанычлылык, тотнаклык, игелеклелек, сүздә торучанлык кебек иң югары мактаулы сыйфатларга, кеше әхлагының бөеклегенә бәйле гаять кимчелексез бик күп шигырьләр укып, гарәп телендә иҗат ителгән әдәбиятка карата мәхәббәтем уянды. Тик мин һаман да гарәп телендә язылган шигырьләрне югары фикерләрдән, галәме-вөҗүднең никадәр тирән хикмәткә ия булуына кагылышлы фәлсәфәдән, адәм баласының яшәеше серләренә кагылышлы тирән фикерләрдән мәхрүмдер дип уй-*

[1] Ягъни: «Барлыкның кирәклеген исбат итү рисаләсе (мәкаләсе, китабы)».

*лый идем. Тик ахырда гарәпләрнең шигъри җыентыкларында ул нәрсәләрнең һәрберсенең бик мул булуын күреп, чын мәгънәсендә хәйран калдым»*[1].

Йомгаклап әйткәндә, Муса әфәндене «*Әдәбийат гарәбийә…*»се бүгенге көндә дә актуальлеген югалтмаган һәм үтә дә җитди мәсьәләләрне халыкка аңлаешлы шәкелдә җиткергән әһәмиятле фәнни тикшеренү булып тора. Бу китапка, һичшиксез, тарихчылар, әдәбиятчылар, тел белгечләре игътибар итәргә тиеш.

1907 елда Казанга гыйлем эстәп Әхмәт-Зәки Вәлиди исемле бер егет килеп төшә. Биредә ул Муса әфәнде, аның фатирында еш кына кунак булган Габдерәшит казый һәм ул чакта Казанда яшәгән Мәгъриб галиме Әш-Шинкыйти[2] белән танышып, бу өч галим белән якын дустанә мөнәсәбәт корып җибәрә. Габдерәшит казый белем туплау теләге белән янган Әхмәт-Зәкигә гарәп телен нәкъ менә Муса Бигиевтән өйрәнергә тәкъдим итә. Муса әфәнденең күңеленә бу егетнең гарәп әдәбияты һәм шигърияте белән кызыксынуы бик хуш килә. Муса әфәнде дә, Габдерәшит казый да, Әш-Шинкыйти дә – һәммәсе Әхмәт-Зәки шәкерткә ай саен акчалата ярдәм итеп торалар. Өстәвенә, Муса әфәнде, аерым эш хакы түләп, Вәлидигә гарәп телендә чыгачак хезмәтләренең корректураларын тикшертә, аның рус теле буенча белемен тикшереп тора һәм укыр өчен кызыклы файдалы китаплар бирә. Бу кадәр белемле кеше белән танышуыннан файдаланып, Әхмәт-Зәки

---

[1] Өзек татар теленә тәрҗемә итеп бирелде.

[2] Әш-Шинкыйти (Әхмәд ибн әл-Әмин Әш-Шинкыйти; 1863–1913) – Мәгърибнең хәзерге заманда Мавритания дип аталган өлешенең иң танылган язучыларыннан берсе, тарих белгече. «Әл-Васит фи тәраҗим үдабә әш-Шинкыйт» («Шинкыйт әдипләренең тәрҗемәи хәлләрендә арадашчы», Каһирә, 1958) исемле географик, әдәби һәм тарихи җыентыкның һәм башка күпсанлы дини китаплар авторы.

Муса әфәндедән Тарафа[1] һәм Ибне Дөрәйд[2] исемле мәшһүр гарәп шагыйрьләренең әсәрләрен өйрәнә, гарәп шигърияте буенча сабак ала. Бервакыт Тоган Муса әфәндедән аның Пушкин турындагы фикерен сорый. Муса Бигиев аңа «Русларны үстергән бер гарәп улы», дип җавап бирә. Тоган, шулай ук, Муса әфәнденең үз авызыннан аның рус опералары тыңлавы һәм бу сәнгатьне яратуы турында ишетә.

1908 елда Казанда Муса әфәнде инде искә алынган имам әш-Шатыйбиның гарәп телендә язылган «***Гакыйлә***»[3] исемле әсәренә шәрех язып нәшер итә. Бу гыйльми хезмәт Коръән мосхәфләренең рәсеменә, тагын да төгәлрәк итеп әйткәндә – Коръән айәтләренең тарихи яктан дөрес шәкелләрдә язылышына, ул шәкелләрнең дөреслеген дәлилләүгә багышланган. Имам әш-Шатыйбиның шигъри калыпта язылган гыйльми хөкемнәренең күбесенә Муса әфәнде үзенең аңлатмаларын, ягъни шәрехләрен өстәгән. Бу китап тулысынча гарәп телендә булганга, ул үзен тәрҗемә итүчене көтә.

Шул ук 1908 елда Муса әфәнде «***Китабу таһарати әл-гарәби***»[4] («*Гарәп нәселләренең сафлыгы*») исемле гарәп телендә язылган тагын бер китап бастырып чыгара. Әлеге әсәрне Муса әфәнденең чордашы, мәлики мәзһәбенең күренекле фәкыйһы, тарихчы, тел белгече, синтаксис остасы Әш-Шинкыйти хәзрәт язган булган. Муса әфәнденең әлеге

[1] Тарафа (Әбу Гамр Тарафа ибн әл-Габед әл-Бәкри) – VI гасырның танылган гарәп шагыйре, мөгаллякъ дип аталган (ягъни Кәгъбә диварына асылган), ислам дәверенә кадәр иҗат ителеп, язуда теркәлгән иң мәшһүр җиде касыйдәнең берсен язган автор.

[2] Ибне Дөрәйд (Әбу Бәкер Мөхәммәд ибне Хәсән ибне Дөрәһд әл-Газди; 838–933) – күренекле гарәп шагыйре, тел галиме; гарәп һәм, гомумән, Шәрык әдәбияты тарихына кереп калган шигъри җәүһәрләр авторы.

[3] Муса Җаруллаһ Рустуфдуни. Китабу гакыйләти атраби әл-касаъиди фи әсна әл-макасыйд. Казань: Типография Т-го Д-ма «Братья Каримовы», 1908. 72 б. («Касыйдәләрнең чордашларын иң балкып торган максатлар хакында акыллыландыру»).

[4] Муса Җаруллаһ Рустуфдуни. Китабу таһарати әл-гарәби. Казан, 1326 h. 48 б.

китапка гарәп телендә язган кыска гына кереш сүзеннән аңлашылганча, әш-Шинкыйти хәзрәтләре Русия мөселманнары тормышы белән танышкан сәфәре дәвамында һиҗри 1326 елның рамазан (1908 елның сентябрь-үктәбер айлары) аенда Казан шәһәрен зиярәт итә. Биредә ул Муса әфәнде һәм җирле татар җәмәгатьчелегенең башка күренекле вәкилләре белән таныша. Шуларның үтенече буенча, Муса әфәнденең сүзләре белән әйткәндә, «ислам динен вә аның пәйгамбәрен яклау» һәм христиан авторларның гарәп кавеменең, шул исәптән Мөхәммәт пәйгамбәрнең дә нәсел тамырларына тел тидереп, мөселманнарга каршы һөҗүманә төстә язылган әсәрләренә җавап бирү йөзеннән әш-Шинкыйти искә алынган китабын язып калдыра. Бу китап та үзен тәрҗемә итүчене көтә бирә.

1908 елда Муса әфәнде башкарган тагын бер әһәмиятле хезмәт турында да әйтеп узарга кирәк. Сүз аның 1902 елда фаҗигале вафат булган абыйсы Мөхәммәт-Заһирдан кульязма хәлендә калган сәфәрнамәне «***Мәвараэннәһердә***[1] ***сәйахәт***»[2] исеме белән бастырып чыгару турында бара[3]. Муса әфәнде бу әсәрне басмага әзерли һәм «*Мөхәммәт Заһир әфәнде Бигиев*» дигән кереш сүз яза. Аны биредә китерәбез: «*Әүвәлдә эшлекле, шөһрәтле, бай улуб, соңра русча-исламча галимле-*

---

[1] Мәвараэннәһер (Трансоксания) – гарәп теленнән «елганың аръягы» дип тәрҗемә ителгән бу төшенчә гарәп гаскәрләре VII–VIII гасырларда, Урта Азиягә бәреп кереп, яулап алу сугышлары алып барганда барлыкка килә. Башта бу төшенчә Җәйхүн (Әмудәрья) елгасының уң яры ягында җәелеп яткан чиксез далаларны белдерә. Соңрак бу төшенчә белән Сәйхун (Сырдарья) елгасы белән Җәйхун елгалары арасында урнашкан биләмәләр белдерелә башлый.

[2] «Мәвараэннәһердә сәйахәт» – Мөхәммәт-Заһир Бигиевнең 1893 елда Идел буе, Каспий һәм Төркестанга (Мәвараэннәһергә) кыйлган сәяхәттән алган тәэсирләрен, Мәвараэннәһер халыкларының авыр тормышларын, Россиянең колониаль сугышларына каршы көрәш күренешләрен, бер уңайдан татар халкының язмышы турындагы уй-фикерләрен үз эченә алган кульязмасы нигезендә әзерләнгән әсәр.

[3] Мөхәммәт Заһир Бигиев. Мәвараэннәһердә сәйахәт. Трансоксаниyйә сәфәр. Казан: «Китап» нәшр., 1908. 108 б.

*генә күрә мөфти Сәлим-Гәрәй хәзрәтләре тарафындан Дон областендә ахундлык рөтбәсендә*[1] *насыб улынмыш*[2]*, йәше кырык бишләрә восульдән каблә*[3] *бөек бер бәлайә ибтиля*[4] *соңында вафат улмыш имам Җаруллаһ бин Габделкәрим Бигиев хәзрәтләренең 25 баласындан бередер. 1870 сәнәләрдә Ростов Донда дөньяйа килмешдер.*

*Заһир әфәнде йашь бала икән русча уку-йазу үгрәнүб, соңра вәлидәсе*[5] *Фатыйма ханым бинт Хәбибуллаһ хәзрәтләренең тәрбиясендә иске мәдрәсәләрнең берендә күб йыллар калуб, иске ысул үзәрендә голүм динийә, голүм гарәбийә укумышдыр. Шу сәнәләр әснасендә йалңыз кәндүсенең сәгъйыйлә*[6] *мәшһүр русларның әсәрләрене мөталәга кыйла*[7] *килмешдер.*

*Йашь икән каләм хидмәтенә рагбәте бөек*[8] *улдыгына күрә, иң ибтида «Пагун за миллионами» нам*[9] *рус әсәренә тәкълидән*[10] *«Гүзәл кыз Хәдиҗә»*[11] *намында бер әсәр йазмышдыр. Шу әсәр Казан шивәсендә*[12] *роман намында йазылмыш әсәрләрнең иң мөкаддәмедер*[13]*. Шагердләрә бер йул йазу йазмак гаеб хисаб улынур бер заманда йазылмышдыр. Ходайның йакты көне кеби бәнем хатеремдәдер ки: Казан халкы, Казан таләбәләре мескин Заһир әфәндейи шу әсәрейлә истихфаф*[14] *идәрләр иде.*

---

[1] Рөтбә – мәртәбә, дәрәҗә.

[2] насыб улынмыш – билгеләнгән; куелган.

[3] восульдән каблә – ирешкәнче; килеп җиткәнче.

[4] бәлайә ибтиля – бәлагә юлыгу.

[5] вәлидәсе – әнисе.

[6] кәндүсенең сәгъйыйлә – үзенең тырышлыгы белән.

[7] мөталәга кыйла – укый.

[8] рагбәте бөек – теләге зур.

[9] нам – исем, исемле.

[10] тәкълидән – ияреп.

[11] «Гүзәл кыз Хәдиҗә» («Өлүф, яки гүзәл кыз Хәдичә») – М.-З. Бигиевнең Казанда 1887 елда чыккан әсәре.

[12] шивәсендә – сөйләшендә, диалектында.

[13] мөкаддәмедер – беренчеседер.

[14] истихфаф – көлкегә калдыру, мыскыл итү.

*Заһир әфәнде шу әсәрене табыг итдермәк касдыйлә*[1] *Казана килүб, Казан мәдрәсәләрендә бер шәй вардыр хыялыйлә «Күл буе» мәдрәсәсендә дәрес укумак өмидейлә калмыш иде. У вакыт Казан шагердләренең әхвәленә ашналык*[2] *пәйда идүб, «Гөнаһ-ы кәбаъир»*[3] *намында шагердләр хәлендән бәхәс идәр бер роман йазды.*

*Бундан соң Ростов Дон шәһәренә кайтуб имам улмыш исә дә гомеренең ниһаясенә кадәр валидәсенең тәрбиясендә калды. Кесәсендә бер парә, бүлмәсендә бер китаб булынмазды. Ростов шәһәренең көтебханә-и гомумиясенә варуб, даимән рус әсәрләрене мөталәгa идәр иде. Шу әснада шагердләрнең хәлендән, иске мәдрәсәләрнең Русия мөселманларына сүъ-и тәэсирендән*[4] *бәхәс идәр*[5] *«Мөртәд»*[6] *намында бер шәй йазды, табыг итдермәк хосусында нәкадәр иҗтиһад итмеш исә дә, улмады.*

*Бундан соң Русиядә хатун-кызларның мазлумиятләрене, тәрбиясезлекләрене күстәрүб, «Катилә»*[7] *намында бер әсәр йазды. Шу әсәр, билмәм насыл, гаять бөек бер мәһарәтлә йазылмышдыр; әсәрләре арасында иң беренчеседер. Бән ул «Катилә»дә Мәрьям ханым илә кызы Әсманың адәм күңеле тәхәммел итмәз*[8] *дәрәҗәдә дәһшәтләрене күрүб, соңра «Сәфилләрә» дә Фантина илә кызы Кузина дәһшәтләрене укудым. Шу ике китаб арасында гаять бөек бер мөнәсәбәт*

[1] касдыйлә – максаты белән.

[2] ашналык – таныш булу; якыннан белү.

[3] «Гөнаһ-ы кәбаъир» («Олуг гөнаһлар») – Мөхәммәт-Заһир Бигиевнең Казанда 1890 елда нәшер ителгән романы. Басмаларының берсе 1925 елда чыга: Бигиев З. Олуг гөнаһлар. Роман. Мөхәммәдзаһир мәрхүм ахунд мулла Җарулла углы Бигиев әсәредер. Татарстан Халык Мәгариф комиссариаты хозурындагы Гыйльми Үзәк каравында басылды. Казан: Татарстан матбугат-нәшрият комбинаты, 1925. 64 б.

[4] сүъ-и тәэсирендән – начар тәэсире турында.

[5] бәхәс идәр – сөйләгән; хикәя кыйлган.

[6] «Мөртәд» – кульязмасы сакланмаган, басылмый калган әсәр.

[7] «Катилә» – кульязмасы сакланмаган, басылмый калган әсәр.

[8] тәхәммел итмәз – күтәрә алмас.

*булдым. Билмәдем: Заһир әфәнде Виктор Һуго*[1] *җәнабләренең сәфилләрене «Казан романы» калыбында йазмышмы? Йахуд кәндүсенең кувә шигърияселә уйлә бер китаб мәйдана чыкармышмы? Уйлә улса да, буйлә улса да бәһр-е тәкъдир*[2] *у китаб Заһир әфәнде намына һәр вакыт фәхер*[3] *улаҗак бер китабдыр. Беркач сәбәбләрлә кәндүсенең хәйатендә табыг улынмады. Иншәъә Аллаһ ганкариб табыг улынур*[4].

*Соңра бер мөһим эш хосусында әмир хәзрәтләрене күрмәк касдыйлә Заһир әфәнде Бохарайа варды. Шу мөнәсәбәтлә Мәвараэннәһери сәйәхәт идүб, рожугы соңында*[5] *бундан унбиш сәнә мөкаддәм йазды.*

*Хөкем-е Ходай илә шу әсәре әсәрләренең хатимәсе улуб, гаять бөек мөдһиш бер бәлайә ибтилясы соңында, 20 нҗе гасыр мәдәниятенең ибтидасында кәндүсенең фирашында*[6] *икән Заһир әфәнде дәст-е хыянәтлә*[7] *кател улынуб шәһид улды. Вәлидәсе баласының җәсәдене табиблар әлендә туградтмамак ичүн бөек парәләр сарыф идүб, ун сәгать мөкаддәм саг-сәламәт шәһәрдә гизмеш бер адәми галәл-гаҗлә дәфен итдермешдер.*

*Хәл-е хәйатендә*[8] *кәндүсе дә, каләме дә игътибарсыз иде*[9]. *Соң сәгатьдә дәме*[10] *дә һәдер улуб*[11] *китдә. Ли әҗли зәлик*[12] *бән, бәнем бәрадәрем әсәрләрене нәшер идүб нам галияләре-*

---

[1] Виктор Һуго (Виктор Мари Гюго; 1802–1885) – француз язучысы, шагыйрь, драматург, Франция романтизм әдәбиятының төп фигураларыннан берсе; дәүләт, сәясәт һәм җәмәгать эшлеклесе.

[2] бәһр-е тәкъдир – һәр очракта, һәрхәлдә.

[3] фәхер – горурлык, дан.

[4] ганкариб табыг улынур – якын арада басылыр.

[5] рожугы соңында – кайтуыннан соң.

[6] фираш – ятак, түшәк.

[7] дәст-е хыянәтлә – хыянәт кулы белән.

[8] хәле хәйатендә – исән чагында.

[9] игътибарсыз иде – санга сугылмый иде.

[10] дәме – каны.

[11] һәдер улуб – әрәм булып.

[12] ли әҗли зәлик – бу йөздән, шуңа күрә.

*не ихъйа итмәк*[1] *йулында сәгъйи идән Габдеррахман әфәнде Хөсәенов*[2] *хәзрәтләренә халис тәшәккүратеми*[3]*, ихтираматеми тәкъдим идүб, бундан соң у биш әсәрләр нәшерене дә Габдеррахман әфәндейә тәхсыйс идәрем*[4].

Муса Бигиев

*Казан, гыйнвар 25 сәнә 1908*»

## Коръәндәге хаталарны төзәтү мәсьәләсе

1909 ел Муса әфәндәнең язмышында аеруча мөһим вакыйгаларга бай булып чыга. Беренчедән, бу елның башында әле һаман да Казанда яшәгән Муса әфәнде «әл-Ислах» гәзитенең 18 гыйнварда чыккан «*Иң лязем бер игълан*» мәкаләсендә Коръән кәримнең мәшһүр Казан басмаларында күпсанлы хәреф хаталары табуы турында игълан ясый.

Башта бу дәгъва Казан мөселманнарының ачуын чыгара, татар бистәләрендә гөрләп торган халык арасында төрле имеш-мимешләр йөри башлый, хәтта милли шагыйребез Габдулла әфәнде Тукай[5], Муса Бигиевне чеметтереп, сатирик шигырь дә язып өлгерә. Тавыш-гаугалар чыгырдан чыга башлап, халыкның тәмам фетнәләнүенә битараф калмаган Казан бае Мөхәммәт-Рәхим әфәнде Юнысов әлеге киеренке мәсьәләне мәйданга чыгарып хәл иттерү өчен, Муса әфәндене һәм аңа каршы чыгучы танылган дин әһелләрен үзенең өендә дәгъвәт итеп, махсус гыйльми җыен үткәрергә тәкъдим итә[6]. Чакырылганнар дәгъвәтне кабул итәләр. Әлеге

[1] нам галияләрене ихъйа итмәк – югары исемен terелтү.

[2] Габдеррахман Хөсәенов (?–?) – иганәче һәм нашир.

[3] тәшәккүратеми – шөкерләремне.

[4] тәхсыйс идәрем – хаслыйм, тапшырам.

[5] Габдулла Тукай (Мөхәммәт-Гариф углы Габдулла Тукаев; 1886–1913) – татар халык шагыйре, әдәби тәнкыйтьче, публицист, җәмәгать эшлеклесе, тәрҗемәче.

[6] Тәсъхыйхы рәсме хатты Коръән. Казан: «Бәйанел-хак» идарәсе, 1909. Б. 01. (өземтә алынган сәхифәне 01 нче бит дип күрсәтү сәер булып күренә, әмма бу китапның үзенчәлекләренә бәйле: гадәттә гонван (титул) сәхифәсе беренче булып санала. Бу тәртип белән барганда Мөхәммәт-Рәхим Юнысовның әлеге тәкъдиме 4

мөзәкарәләрнең, ягъни фикер алышу өчен үткәрелгән ике җыелышның, барышын «Бәян әл-хак» гәзитендә хәбәрче булып эшләгән журналист Сәгыйт Рәмиев[1] яктыртып бара. Февральнең 7-сендә үткәрелгән беренче мөзәкарә җыелышы башланганда гомуми саны өч йөздән артып киткән халыкның ярсып-кызып Муса әфәнденең дәгъвасына карата гауга кубаруы ихтималын аңлаган могътәбәр дин әһелләре, бу чараның дилбегәсен җәһәт кенә үз кулларына алып, мәҗлес тәртипле-саллы сурәттә үткәрелсен өчен араларыннан рәис белән сәркатип билгелиләр. Рәис эш алып бару һәм чыгышлар тәртибен игълан итә дә, мөзәкарә җайга салынып эшен башлый. Аннары Муса әфәнде үзенең бу скандаллы адымының сәбәпләре турында кыска гына сүз тота. Аның әйткәннәрен Сәгыйт Рәмиев түбәндәге сурәттә теркәп калдырган: «*Мин бу мәсьәләне ни өчен газитәгә яздым? Чөнки тәсъхих-е Коръән мәсьәләсе – гаять мөһим мәсьәлә, Коръәнгә һичкем үз белдеге белән генә бер хәреф тә арттыра алмый, шулай ук үз белдеге белән генә Коръәннән бер хәреф тә киметә алмый, әгәр мин мондый мөһим мәсьәләне гәзитәләр белән гомум әһле исламга хәбәр итмичә, бер-бер газиз остазым яки бер-бер галим янына гына барып: «Коръәннең бу җире яңлыш икән, без моны синең белән икәү төзәтик», – дисәм, ул минем тарафымнан Коръәнгә бик зур җинаять булыр иде. Мин шул җинаятьне итмәс өчен саф гарыз сахих*[2] *белән генә, һичбер халык арасына да фетнә чыгаруны уйламыйча, саф хаклыкны күрсәтү өчен генә бу мәсьәләне гәзитәләрдә игълан иттем. Аннан соң, ни өчен мин бу мәсьәләне хосусый Казанда кузгалттым? Чөнки Казан – голәма вә мөгаллимнәрнең күп җире. Әгәр мин бу мәсьәләне Казанда кузгалтмыйча, икенче бер җирдә кузгалт-*

---

нче биткә туры килә. Әмма китап сәхифәләренең нумерациясе буенча 1 нче сәхифә итеп күрсәтелгән бит гонваннан санап барганда 5 нче бит булып чыга. Бу буталчыкны китапны бастыручыларның бер игътибарсызлыгы буларак кабул итәргә кирәк.

[1] Сәгыйт Рәмиев (Лотфулла углы Сәгыйт Рәмиев; 1880–1926) – шагыйрь, драматург, публицист.

[2] гарыз сахих (عرض صحيح) – яхшы ният.

*сам, шөбһәсез, миңа әйтерләр иде: «Син Казанда булдың, анда голәма күп иде, ник моны Казанда әйтмәдең, син ахмак», – диярләр иде. Шуның өчен мин моны Казанда ачтым. Печән базары фетнәләнсә фетнәләнсен, әмма Коръәнебезгә яңлыш кермәсен! 1327 ел буена Коръәнебез, хәмед булсын, тәхриф ителмичә[1] килде. Борынгы галимнәр Коръәннең язылыш рәсеменә, язуда теркәлүенә, төзелешенә гаять игътина[2] итә килделәр, әгәр без дә алар игътина иткән кебек игътина итмәсәк, Коръәнебез ни хәлгә калачак? Тәхрифкә юл ачылачак түгелме? Әлбәттә, тәхрифкә юл ачылачак! Шуның өчен мин бу мәсьәләне гаять мөһимгә санап, гәзитә сәхифәләрендә тараттым, Аллаһ белә, гарызым[3] бозык түгел, гарызым бары яхшылыкта гына*».

Бу нотыктан соң мәҗлескә җыелганнар Коръән язылышы (рәсеме) төшенчәсе турында фикер алышуга күчеп, аның аерылгысыз өлеше буларак хәлифәи Госман дәверендә рәсмиләштерелгән язылыш рәсеменең булуын да искәртеп, Коръән мосхәфләрен бастырганда Госман заманында теркәлгән язылыш рәсеменә иярүнең тиешле яки тиешсез булуы мәсьәләсе турында җитди гыйльми бәхәскә күчәләр. Муса әфәнде дә бәхәстән читтә тормый, әлбәттә. Аңа сүз бирелгәч, ул кешелек дөньясында язуның әһәмияте һәм аның тарихы турында сөйли, аннары Мөхәммәт пәйгамбәрнең килүенә кадәр гарәпләрдә язуның таралган булуын дәлилләп, пәйгамбәрнең сәхабәләре арасыннан уку-яза белгәннәренең исемнәрен бәйнә-бәйнә санап чыга. Гомумән алганда, Муса әфәнде үзенең лекциягә тиң булган бу чыгышында Коръәннең хәлифәи Госман заманында түгел, ә аннан алда, хәтта Мөхәммәт пәйгамбәр исән чакта ук, тулы сурәттә язуда теркәлгән булуын дәлилләп халыкка җиткерүне күздә тоткан була.

Юнысов йортында үткәрелгән чара шул кадәр резонанслы була ки, ул хәтта рус телле матбугатта да чагылыш таба. Мәсәлән, Казанда чыгып килгән «Восточный листок» гәзи-

[1] тәхриф ителмичә – үзгәртелмичә, бозылмыйча.

[2] игътина (اعتنا) – әһәмият бирү, игътибар итү, кайгырту.

[3] гарыз (عرض) – белдерү, тәкъдим, дәгъва.

тенең 804 нче санындагы «Мусульманская жизнь» рубрикасында Юшков исемле берәү мондый хәбәр урнаштыра: «*Татарский «Никон»*[1]. *Недавно в г. Казани поселился некий Муса Бигиев, мусульманский богослов и ученый, задавшись целью исправить в Коране орфографические ошибки. По мнению Бигиева, в Коране масса ошибок, среди которых есть и такие, которые искажают смысл святого писания. Основное положение Бигиева заключается в том, что прототипом для правописания нужно считать Коран Османа, а не какой-нибудь другой.*

*Третьего дня по этому поводу в доме М. Юнусова состоялось многолюдное собрание из местных мулл, учителей и интеллигентной части мусульманского общества. В этом собрании Бигиев подробно развил свое «учение». Прогрессивная часть мусульманского общества с иронией отзывается о выступлении нового толкователя-исправителя Корана. Бигиев – еще молодой человек*».

Беренче җыелышның кызу мохиты һәм киеренкелеге Муса әфәндене «әл-Ислах» гәзитенең 18 февраль санында «*Рәсме Коръән*»[2] исемле мәкалә бастырып чыгарырга этәрә. Шулай итеп, галим үзенең дәгъвасын һәм фикерләрен Юнысовлар йортының кысаларыннан иреккә чыгарып, киң күләм халык массаларына ирештерүен дәвам итә.

---

[1] Никон (Никита Минин; 1605–1681) – Рус Чиркәве Патриархы. 1650 елларда Рус Чиркәве йолаларын юнан (грек) кагыйдәсенә яраштыру өчен реформалар башлый. Моның нәтиҗәсендә Рус Чиркәве бүленә, «искейолачылык» (старообрядчество) дип аталган мәзһәб барлыкка килә. 1666 елда патриархлыктан куыла, әмма дин инде элекке хәленә кайтарылмый һәм үзгәртелгән шәкелендә рәсмиләштерелә.

[2] рәсме Коръән – хәлифә Госман дәверендә (милади 644–656 елларда) җыеп бетерелеп, язма рәвештә теркәлгән Коръәннең рәсми шәкеле, ягъни андагы хәрефләрнең, сүзләрнең, сүзтезмәләрнең катгый язылыш кыяфәте, үзгәртелүе ярамаган рәсми калыбы яки орфографиясе.

Февральнең 21 ендә Юнысов йортында Муса әфәнде күтәргән мәсьәләгә багышланган икенче җыелыш үткәрелә. Яңадан кызу бәхәсләр куба, ахыр чиктә, Коръән рәсемен, ягъни язылышын, Госман Коръәненә туры китереп язуның дөреслеге һәм тиешлеге турында килешүгә ирешелә. Халыкны бу фикергә күндерүдә, беренче нәүбәттә, Муса әфәндене гыйльми нотыклары зур роль уйный булса кирәк. Бу җәһәттән, шундый бер чыгыштан өзек китерү урынлы булыр. «*Сәхабәләрдә язу*» исемле нотыгында Муса әфәнде мондый сүзләр әйткән: «*Ислам дине барлыкка килгән вакытта Мәккәдә язу гаять мәгъруф, ягъни билгеле иде. Хәтта хатын-кызлар арасында да байтак кына яза белүчеләр булган. Хәдис китапларындагы риваятьләргә күрә беләбез ки, хәзрәт-и Гомәр ислам динен кабул иткәнгә кадәр, аның кыз кардәше Та-Һа сүрәсен язып алып, өендә качып шуны укый торган булган.*

*Ирләр арасында да ул вакытта язуны белүчеләр бик күп булган. Андыйларның иң мәшһүрләре: Әбү Бәкер, Гомәр, Госман, Гали, Зүбәйр, Гамир бине Фүһәйра, Гамру бине әл-Гас, Үбәй бине Кәгыб, Габдулла бине Әркам, Сабит бине Кайс, Хәнзалә бине әр-Рабигъ, Могыйра бине Шөгъбә, Габдулла бине Равәхә, Халид бине әл-Вәлид, Халид бине Сәгыйд, Мөгавия, Зәид бине Сабит, Тальхә, Госман бине Сәгыйд, Әбән бине Сәгыйд, Йәзид бине Әби Суфиян, Хатыйп бине Гамру, Галә бине әл-Хадрами, Әбү Сәлма бине Габд әл-Әшһәл, Габдулла бине Сәгъд, Хувәйтыб бине Габд әл-Гуззә, Әбү Суфиян бине Хәрб, Җүһәем бине әс-Салт кебек адәмләр язу язудагы осталыклары белән дан-шөһрәт казанганнар иде. Һиҗрәттән соң сәхабәләр, язу мәсьәләсен кайгыртып, яшь балаларына язу өйрәтә торган булганнар. Әнәс ибне Мәлик, Ибне Гомәр, Ибне Гамру, Ибне Габбас кебек яшь сәхабәләр һәммәсе язуда осталыкка ирешкәннәр.*

*Шөбһәсез, сәхабәләр арасында яза белә торганнары гаять күп булган. Ләкин язуны дөрес итеп язарлык осталык бар идеме? Моңа җавап бирер өчен мин хәзер дүртенче мәсьәлә-*

*не бәян итим. Сәхабәләр язуы белән фән ияләренең язуын чагыштыру.*

*Без әгәр Госман мосхәфләренең язылышын тикшерсәк, фән ияләре каршында кабул ителгән кагыйдәләрнең һәрберсенең мосхәфлар язылышыннан алынганлыгы безгә мәгълүм булыр. Васыл кагыйдәсе*[1]*, фасыл кагыйдәсе*[2]*, зиядә*[3] *һәм хәзеф*[4]*, соңыннан вакыф*[5] *һәм ибтидаъ*[6] *хәлләрен үтәү кагыйдәләре – болар һәммәсе мосхәфләр язылышыннан алынган. Гарәп язуында иң мәшәкатьле булган һәмзә хәрефен язу кагыйдәләре тулысынча мосхәфләрдән алынган. Әгәр фән ияләре каршында кабул ителгән Коръән язылышын чын дип таныйбыз икән, димәк Госман мосхәфенең язылышын кабул итү, әлбәттә, важҗип булачак*»[7].

Фәнни яктан төпле һәм инандырырлык белешмә биргәннән соң, Муса әфәнде Коръәннең Казан басмасындагы язылыш хаталарын берәм-берәм күрсәтеп, хаталарның нидән гыйбарәт булуын аңлатып бирә. Мисал өчен, Муса әфәнденең Казанда басылган Коръәннәрдә тапкан хаталарга кагылышлы бер өзек китерик:

«*Рум сүрәсендә 10 нчы айәтдә «اساوا» кәлимәсе*[8]*. Шу кәлимәдә «уау»дан соңгы «әлиф» Казан мосхәфләрендә заммә*[9] *белән забыт кыйлынмышдыр*[10]*. Шу забыт өч җиһәтдән хатадыр: бере: «уау»дан соңгы «әлиф» كانوا «әлиф»е кеби укынмаз «әлиф»дер. Укынмаз «әлиф» үзәренә*[11] *дә заммә куймак, әлбәттә, хатадыр. Икенчесе: «اساوا» кәлимәсендә укы-*

---

[1] васыл – кушу билгесе һәм кагыйдәсе.

[2] фасыл – аеру, бүлү; аеру билгесе һәм кагыйдәсе.

[3] зиядә – кушу (арттыру) кагыйдәсе.

[4] хәзеф – төшереп калдыру кагыйдәсе.

[5] вакыф – тукталыш ясау; туктап тору.

[6] ибтида – башлап җибәрү.

[7] Өзек татар теленә тәрҗемә ителеп бирелде.

[8] Госман мосхәфләрендә әлеге сүз أسوا рәвешендә язылган (Коръән, 30:10).

[9] заммә – кыска у/ү сузык авазларын белдерүче хәрәкә (билге).

[10] забыт кыйлынмыш – теркәлгән.

[11] үзәренә – өстенә.

*ныр «әлиф» «уау»дан каблә*[1] *укыныр, Казан мосхәфләрендә укыныр «әлиф» «уау»дан соң забыт улынмышдыр. Өченчесе: Казан мосхәфләренең забытына күрә, вакыфда мәдд*[2] *белән вакыф итмәк мөмкин түгелдер. Ләкин «اساوا» кәлимәсендә вакыф иткәндә, мәдд, әлбәттә, ляземдер.*

*«Кяһеф» сүрәсендә 98 айәтдә «دكاء» кәлимәсе*[3]*. Казан мосхәфләрендә «кяф»дан соңгы «әлиф» үзәрендә фәтхә куелмышдыр. Шу забыт ике җиһәтдән хатадыр: бере «кяф»-дан соңгы «әлиф» «һәмзә» түгел, «كتاب» «әлиф»е кебек хәреф мәддтер. Фәтхә белән забыт итмәк, шөбһәсез, хатадыр. Икенчесе: Казан мосхәфләренең забытына күрә вакыф хәлендә каср*[4] *җаъиз*[5] *буламаз. Ләкин әһле кыйраәтнең*[6] *иттифакы*[7] *белән каср җаъиздыр*[8]*»*[9]*.*

Әлеге өзектән аңлашылганча, Муса әфәнде Казанда басылган Коръәннәрдә хаталарны табу белән генә чикләнмичә, һәр хатаның ни өчен ялгыш булуын да аңлаткан һәм аларны төзәтү юлларын да күрсәткән. Изге китап язылышында бу кадәр күп ялгышларның булуын күреп, Казан голәмәсе башта аптырап калалар, аннары, мәсьәләнең җитдилеген аңлагач, аны хәл итү өчен махсус комиссия оештырып, ачыкланган бу хәлне тирәнтен өйрәнү һәм хаталарны төзәтү эшенә тотыналар. Комиссия Казан басмасы Коръәннәрендәге хаталарны Истанбулда, Каһирәдә, Һиндестанда чыккан мосхәфләрдә дә табып, чит илләрдә типографик ысул белән Коръән нәшер итүчеләрнең игътибарын бу җитди мәсьәләгә җәлеп итәр өчен аларга рәсми мөрәҗәгать юллый.

---

[1] каблә – алда, элек.

[2] мәдд – сузык авазны сузып укуның тиешле булуын күрсәтүче билге.

[3] Коръән, 18:98.

[4] каср – авазны кыскартып әйтү.

[5] җаъиз – ярый торган, рөхсәт ителгән.

[6] әһле кыйраәт – Коръән укуның (кыйраәт) осталары.

[7] иттифак – уртак ризалык; бертавыштан килешү.

[8] Тәсхыйхы рәсме хатты Коръән, б. 65–66.

[9] Өзек татар теленә яраклаштырылып бирелде.

Җыелышта күтәрелгән мәсьәләләргә караган аңлатмаларын Муса әфәнде татар матбугаты аша халыкка ирештерүен дәвам итә: «әл-Ислах» гәзитенең 9 мартта чыккан санында аның «*Коръән кәримнең рәсеме*» һәм «*Гарәпләрдә язу тарихы*» исемле ике мәкаләсе, «Бәян әл-хак» гәзитенең 10 март санында «*Игътизар*» һәм «*Коръән кәрим рәсме хакында бер-ике сүз*» исемле мәкаләләре дөнья күрә.

Ниһаять, Казан мосхәфләрендәге хаталар турындагы гыйльми бәхәсне халыкка җиткерү йөзеннән, «Бәйанел-хак» нәшрияты[1] «***Тәсъхыйхы рәсме хатты Коръән***»[2] исемле китап бастыра. Бу басманың эчтәлеге җыелышлар барышын яктырткан Сәгыйт Рәмиев репортажларыннан (б. 2–43) һәм Муса Бигиев тарафыннан язылган «*Әдиб мөхтәрәм Муса әфәнде Бигиев җәнабләренең дәлилләре*» дип аталган фәнни фасылдан (б. 43–93) гыйбарәт була.

Шулай итеп, 1909 елның башында булып алган вакыйгалар нәтиҗәсендә Муса Җаруллаһ татар дөньясына үзен тирән белемле Коръән белгече буларак танытып өлгерә һәм, шул вакыттан башлап, аның исеме татар дини һәм фәлсәфи фикере мәйданында үзенә лаеклы мәртәбәле урын яулап ала.

### Оренбург: «Хөсәения» мәдрәсәсендәге вакыйгалар

1909 ел вакыйгалары Муса әфәнде өчен, Казан басмалы Коръәннәрдәге хаталарга багышланып, Казанда үткәрелгән җыелышлар белән генә тәмамланмый. Аталган елның язынҗәен ул Казан белән Чистай арасында үткәрә, ә сентябрь аенда Оренбург шәһәренә юл тота. Татар халкының бу олы милли-мәдәни үзәгенә Муса әфәндене Ризаэтдин хәзрәт

---

[1] «Бәян әл-хак» нәшрияты – Казан сәүдәгәре Яхъя углы Әхмәтҗан Сәйдәшев (1840–1912) оештырган нәшрият (идарә) һәм шул ук исемле гәзит. Гәзитнең беренче саны 1906 елның 31 мартында чыга.

[2] Тәсъхыйхы рәсме хатты Коръән. Казан: «Бәйанел-хак» идарәсе, 1909. 94 б.

Фәхретдин[1] чакырып алган булса да, бу дәгъвәтнең үз тарихы бар.

Муса әфәнде «Хөсәения» мәдрәсәсенең[2] мөдире булырга теләп һәм бу эштә ярдәм сорап «Шура» журналының[3] мөхәррире Риза хәзрәт Фәхретдингә хат язган була. Риза хәзрәт Бигиевнең үтенечен кабул итә, гәрчә үзе дә ул чакта мәдрәсә мөдире кәнәфиенә өмет баглаган булса да. Чөнки Муса әфәндегә үзенең көндәше, конкуренты буларак түгел, татар милләтен агарту һәм тәрәккъый иттерү эшенә зур өлеш кертә алырлык галим итеп карый. Риза хәзрәтнең максаты да ачык: Бигиев мөдир буламы, юкмы – анысын мәдрәсә иганәчеләре хәл итәр, тик үзен дин гыйлеменең төрле тармакларында зур белгеч буларак танытып өлгергән яшь галим, әлбәттә, данлыклы «Хөсәения» мәдрәсәсендә укытырга тиеш!

Чыннан да, җәдит мәдрәсәнең җитәкчелеге, Муса әфәндегә зур өметләр багълап, диннәр тарихы белән бергә аңа гарәп теле һәм әдәбияты тарихы, *фикъһы* (ислам хокукының теориясе һәм практикасы) һәм *гыйльме әхвале рух* (психология) буенча дәресләр укытуны да тапшыра һәм атнага утыз сәгать дәрес йөкли. Муса әфәнде Оренбургка барып урнаша да, 1909 елның октябрь башыннан укытуга керешә. Сүз уңаен-

---

[1] Ризаэтдин Фәхретдин (Фәхретдин углы Ризаэтдин Фәхретдинов; 1859–1936) – күренекле дин һәм җәмәгать эшлеклесе, дин галиме, татар дини ислях хәрәкәтен әйдәп баручыларның берсе; мәгърифәтче, тарихчы, археограф, нашир, публицист; күпсанлы китаплар һәм мәкаләләр авторы; 1923–1936 елларда Уфадагы Үзәк Диния нәзарәте мөфтие.

[2] «Хөсәения» мәдрәсәсе – Оренбург байлары Әхмәт (1837–1906) белән Мәхмүт (1839–1910) Хөсәеновлар төзеткән мәчет каршысында 1891 елдан эшли башлаган мәдрәсә. Уку-укыту программасы җәдитчел рухта төзелгән була. 1919–1920 уку елында мәдрәсә «Татар халык мәгарифе институты» ителеп үзгәртелә.

[3] «Шура» журналы – беренче татар әдәби-иҗтимагый журналы, 1908–1917 елларда Оренбургта чыга, җәмгысы 240 саны дөнья күрә. Журналны татар әдәбияты классигы, Дәрдемәнд тәхәллүсе белән иҗат иткән шагыйрь, сәүдәгәр, сәнәгатьче, хәйрияче Садыйк углы Мөхәммәт-Закир Рәмиев (1859–1921) оештыра.

нан, мәдрәсәнең мөдире итеп Габделгалим Дәүләтшин[1] куела, ә Бигиев белән Гыйрфан Рахманкулов[2] аның урынбасарлары итеп билгеләнәләр. Оренбургта Муса әфәнде бер урыс ханымның фатирында бүлмә яллый. Шул ук фатирның икенче бер бүлмәсендә «Вакыт» гәзите[3] хезмәткәре, күп еллар үткәч Муса әфәнденең тормыш юлы һәм иҗатына багышланган китап язачак Габдулла Баттал-Таймас яшәгән була.

«Хөсәения»дә укыткан чагында Муса әфәнденең тормышында булып узган вакыйгалар шулкадәр кызыклы һәм әһәмиятле ки, алар турында сөйләмәсәк, хата булыр.

Беренчедән, мәдрәсәнең уку-укыту программасында диннәр тарихы кебек предметның булуына игътибар итик. «Шура» журналының язуына күрә, әлеге предмет программага 1906 елда кертелгән була. Бу предметны кертер алдыннан мәдрәсә идарәсендә, әлбәттә, фикер алышулар үткәрелә. Шул җыелышларда очар кошка канатлар никадәр кирәк булса, дин әһеленә диннәр тарихын белүнең шулкадәр кирәк булуы турында фикерләр яңгырый. Диннәр тарихын белмәү белән бәйле тискәре мисаллар да искә алына, чөнки «Хөсәения»не тәмамлап чыккан берничә кеше мәхәллә әһеле белән, шул сәбәпле, араларын инде бозып өлгергән булалар.

Диннәр тарихы сабагының эчтәлеген язу өчен мәдрәсәнең иганәчеләре бертуган Хөсәеновлар, Галимҗан Баруди[4],

[1] Габделгалим Дәүләтшин (Габделгалләм углы Габделгалим Дәүләтшин; 1843–1926) – дин эшлеклесе, «Хөсәения» мәдрәсәсе ректоры.

[2] Гыйрфан Рахманкулов (Шәйхелмәрдан углы Гыйрфан Рахманкулов, 1874–1942) – дин һәм җәмәгать эшлеклесе, мөгаллим. Рус-Япон сугышы вакытында Амур хәрби округы штабына мулла булып беркетелә.

[3] «Вакыт» газетасы – 1906–1918 елларда Оренбург шәһәрендә билгеле татар миллионерлары, алтын приискалар хуҗалары Мөхәммәд-Шакир һәм Мөхәммәд-Закир Рәмиевләр исәбенә чыккан гомумрусия татар гәзите. Җәмгысы 2309 саны дөнья күрә.

[4] Галимҗан Баруди (Мөхәмматҗан углы Галимҗан Галиев; 1857–1921) – дин һәм җәмәгать эшлеклесе, дин галиме, Русия мөселман өммәте тарафыннан беренче мәртәбә сайлау нәтиҗәсендә мөфтилеккә каралган кеше (1917–1921).

Ризаэтдин Фәхретдин, Йосыф Акчура, Фатих Кәрими[1] кебек, татар дөньясында инде танылып өлгергән олпат затларны дәшәләр. Әмма диннәр тарихын укытырлык белгеч табылмый. Мәсьәлә хәл ителгәч, «Шура»: «*Әл-хәмде ли-ллаһи, ниһаять, әлеге дәресне укыту вазифасы хөрмәтле Муса әфәнде Җаруллаһның кулына тапшырылды һәм ул инде укыта да башлады*», дигән сөенечле сүзләр язып чыга.

Мәдрәсә идарәсенең диннәр тарихын укытуны Муса әфәндегә тәкъдим итүе очраклы түгел. Беренчедән, бу уку йортының җәдидчел юнәлешле булуын истә тотарга кирәк. «Хөсәения» тарихын өйрәнүчеләр фикеренчә, биредә Бохара һәм Сәмәрканд мәдрәсәләрендә белем алган укытучылар бик аз була. Белем бирү методикаларын сайлау һәм, гомумән, уку йортының кабатланмас эчке атмосферасын булдыру эшендә мәдрәсә идарәсе Аурупа һәм Госманлы дәүләте калыпларына йөз тоткан. Кадрлар сайлау сәясәтенең мондый үзенчәлеге эшкә, күбесенчә, Госманлы Төркия һәм Көнбатыш Аурупа институт һәм университетларын тәмамлаган белгечләрнең алынуына китерә. Алар арасында Русия мөселманнарының иҗтимагый тормышында инде исем казанып өлгергән энциклопедик белем ияләре дә була. Шуңа күрә «Хөсәения»нең тәрәккъыятьчел җитәкчелеге яңа карашлары белән аерылып торган, дини, иҗтимагый, сәяси мәсьәләләрдә тирән һәм күпкырлы белемнәргә ия, эшкә сәләтле, үзенчәлекле фикер йөртүче Муса Бигиевне күрми кала алмаган булса кирәк.

Мәдрәсә шәкертләренә диннәр тарихыннан дәресләр бирү дәвамында Муса әфәнде аларны *рәхмәт илаһия*нең (илаһи мәрхәмәтнең) гомуми булуы, һәрнәрсәне биләп колачлавы турындагы төшенчә белән таныштыра. Инсаният[2] тарихына

[1] Фатих Кәрими (Гыйлман углы Фатих Кәрими; 1870–1937) – җәмәгать эшлеклесе, язучы, мәгърифәтче, педагог, журналист. 1906–1917 елларда «Вакыт» гәзите редакторы. 1917–1924 елларда иҗтимагый һәм сәяси эшчәнлек белән шөгыльләнә, Оренбургтагы уку йортларында укыта. 1925 елдан Мәскәүдә яшәп, Шәрык университетында төрек теле укыта; 100-дән артык уку-укыту кулланмалары, дәреслекләр, публицистик һәм әдәби әсәрләр авторы.

[2] инсаният – кешелек дөньясы; цивилизация.

Аллаһның әлеге «гомуми мәрхәмәте» күзлегеннән караганда, исламга кадәр үткән-кичкән яки, сакланып калып, ислам дине белән янәшә яшәп килгән барлык диннәрнең хак, ягъни дөрес булуын белдереп, Муса әфәнде Аллаһның, кайчан да булса, һәр бәндәсенә, аның диненә, милләтенә карамастан, оҗмах ишекләрен ачып җибәрәчәге турындагы нәтиҗә белән үзенең шаккатыргыч дәгъвасын йомгаклап куя. Әйткән сүзләрен раслар өчен ул Коръән кәримнән, сәхабәләрдән ирешкән хәбәрләрдән һәм олуг суфилар мирасыннан дәлилләр китерә.

Бу идеяләр шәкертләрне никадәр генә аптырашта калдырган, шикләндергән, яки канатландырган булмасын, Муса әфәнденең аларны үзе уйлап тапмаган булуы турында да әйтеп узарга кирәк. Ул моны шәкертләреннән яшерми дә, чөнки Аллаһ мәрхәмәтенең гомумилеге турындагы идеяне югарыда искә алынган әл-Мәгарри белән Ибне Гарәбиләрнең[1] мирасларына таянып хәбәр итә. Шуңа күрә ислам фикере тарихында борынгы заманнарда ук телгә алынган, бәхәсләр кузгаткан әлеге идеяләрне Муса әфәнде, үзенең рухи омтылышларына ияреп һәм гыйлеменә таянып, киңәйтүче һәм дәлилләр китереп баетучы буларак кабул итәлергә тиеш. Чыннан да, Аллаһ мәрхәмәтенең гомумилеге турындагы сүзләр Мөхәммәд пәйгамбәрнең үзе тарафыннан да, аның сәхабәләре тарафыннан да әйтелгән була. Әлеге үтә дә җитди һәм әһәмиятле теманы соңрак дәверләрдә Ибне Тәймийя[2], Ибн әл-Каййим әл-Җәүзия[3] кебек танылган дин галимнәре һәм фикер ияләре дә уңай төстә яктыртканнар. Аллаһ мәрхәмәтенең табигате һәркемгә

[1] Ибне Гарәби (1165–1240) – чыгышы белән Андалусияле (хәзерге Испаниянең бер вилаяте) дин галиме, күренекле суфи, тәсаввыфны үстерүгә зур практик һәм теоретик өлеш керткән зат.

[2] Ибне Тәймийя (Тәкыйетдин Әбу Габбас Әхмәд ибне Габделхәлим әл-Харрани; 1263–1328) – күренекле дин галиме. 500-гә якын хезмәт авторы. Сәясәттә дәүләт белән диннең бердәм булырга тиешлеген дәгъвалаган, халифәтнең мәҗбүри булмавын, бер үк вакытта берничә хәлифә булу мөмкинлеген яклаган.

[3] Ибн әл-Каййим әл-Җәүзия (Шәмсетдин Әбу Габдуллаһ Мөхәммәд ибне Әбу Бәкер әд-Димашкый; 1292–1350) – дин галиме, тәфсирче, хәдис белгече; фәкыйһ; Ибне Тәймийянең шәкерте.

кагылган гомумфәлсәфи бер мәсьәлә булганга күрә, аңа христианнар да игътибар иткәннәр. Мәсәлән, танылган шәркыятьче галим В. Бартольд[1] фикеренчә, мистицизм белән мавыккан христианнар коткарылуның бердәнбер чыганагы булган илаһи мәрхәмәткә теләсә нинди дин әһеленең, шул исәптән яһүдиләр белән мөселманнарның да ирешә алуларына инана торган булганнар.

Әлеге мәсьәләнең һәркемгә кагылып, һәркемнең игътибарын җәлеп итүе Муса әфәнденең диннәр тарихы дәресләрендә ишеттергән идеясенә мәдрәсә кысаларында һәм, гомумән, Русия мөселман җәмәгатьчелегендә булган мөнәсәбәттән бик яхшы күренә: бер яктан, Бигиев дәресләрендә кичергән шоктан соң аңнарына килгән шәкертләр мөдәррисләрен дәррәү кубып хуплыйлар, ә икенче яктан, башта «Хөсәения»нең берничә мөгаллиме бу идеяләргә каршы чыга. Тагын берничә атна узгач – Бигиевнең илаһи мәрхәмәтнең гомумилеге турындагы мәкаләләре, Ризаэтдин хәзрәтнең ризалыгы белән, «Шура» журналында басылып чыга башлаганнан соң – ил хәтле ил мөселманнары Аллаһ мәрхәмәтенең бу кадәр киң булуын һич тә кабул итә алмыйча, ризасызлык сөрәне салалар.

Риза хәзрәтнең Бигиев куйган мәсьәләгә үзенең журналында юлны аңлы рәвештә ачып җибәрүенә дә игътибар итәргә кирәк. Гомумән алганда, Риза хәзрәт әлеге мәсьәләне ахырына кадәр күз уңында тотачак. Ә бу эшне башлаган минутта «Шура»ның 1909 елның ноябрь аенда чыккан 22 нче санында ул мондый сүзләр яза: «*Хәзерге заманда вакытлы матбугат арадашлыгы белән белем алу гадәтен истә тотып, һәм башка мәдрәсәләрдә укучы шәкертләргә дә хөрмәтле Муса әфәнденең дәресләре белән танышырга мөмкинлек бирү йөзеннән, ул дәресләр, кайбер аңлатмалар белән, «Шура» сәхифәләрендә нәшер ителәчәк*».

Шулай итеп, Муса әфәнденең Аллаһ мәрхәмәтенең гомумилеге турындагы язмалары «*Тарих-ы әдъйан: Мөхтәрәм Муса әфәнде дәресе*» рубрикасы астында «Шура»да, 1909 елның

[1] В. Бартольд (Василий Владимирович Бартольд; 1869–1930) – күренекле шәркыятьче галим, тарихчы, ислам белгече, тел галиме; совет шәркыять белеменә нигез салучыларның берсе.

ноябрь аеннан башлап, 1910 елның март аена кадәр чыгып киләләр һәм мөселман җәмәгатьчелегенең кара фанатик өлешен чыгырдан чыгаралар. Бу турыда сүзебез алда әле, ә хәзер мәдрәсә кысаларына әйләнеп кайтыйк.

Һич көтмәгәндә Аллаһ мәрхәмәтенең гомуми булуы белән килешә алмаучыларның хәтта «Хөсәения»дә дә юк түгеллеге ачыклана, чөнки Бигиев тарафыннан шәкертләрнең башларына салган хөр фикерләү оеткысының яшьләр арасында кызу бәхәсләр туфаны кубаруы һәм, алардан мөгаллимнәрнең дә калышмавы аркасында, мәдрәсәдәге психологик атмосфераның кыза башлавы бәгъзыларны бик куркыта. Нәкъ әнә шул мәлдә киеренкелек дәрәҗәсен күтәрә алмаган Габдерахим Дәминов[1] атлы бер мөгаллим тарафыннан Муса Бигиевне укытудан тыю кирәклеге турында мәдрәсә мөтәвәлияте[2] исеменә шикаять гаризасы килеп төшә һәм кабул ителә. Муса әфәнде ялындырып тормый һәм, озакка сузмыйча, үзе үк эштән азат итүне сорап гариза яза.

Муса әфәнде үзенең идеяләрен якларга да тырышып карый. Андый адымнарның берсе итеп, «Вакыт» гәзитенең 16 декабрь санында чыккан «*Иң ахыр сүзем*» исемле мәкаләдә әйтелгәннәрне күрсәтеп була: «*«Шура» сәхифәләрендә бәнем тарафымдан нәшер улынмыш халис*[3] *гыйльми бер мәсьәләдә йә гаҗелән*[4] *йахуд гараз илҗасыйлә*[5] *бәңа һөҗүм идән имам әфәнделәри бер мәҗлес гыйльми гакыд итмийә*[6] *дәгъва итмеш идем*»,– дип яза ул. Тик Муса әфәнденең бу тәкъдимен кабул итмиләр. Бу турыда татар матбугаты сәхифәләрендә мондый сүзләр сакланган:

[1] Алга таба бу кеше «Хөсәения»нең ректоры булу дәрәҗәсенә ирешә.

[2] мөтәвәлиять – мөселманнарга вакыф буларак тапшырылган малны куллану һәм аның белән идарә итү өчен каралган орган. Безнең очракта сүз «Хөсәения» мәдрәсәсенең дә, вакыф малы буларак, мөтәвәлиләр тарафыннан идарә ителүе турында бара.

[3] халис – саф.

[4] гаҗелән – ашыгыч.

[5] гараз илҗасыйлә – махсус сурәттә, юри.

[6] гакыд итмийә – үткәрергә.

*««Дин вә мәгыйшәт»челәр бу дәгъвәт хакында соңгы 48нче нумирында буйлә яза: «Бигиевнең меллаларны үзе илә мөназарага дәгъвәте дә бер мәҗнүннең «Мин кояш эченә сикереп менеп шунда булган мәхлүкатьтән нәмунә*[1] *алып төшеп күрсәтәчәкмен, фән-е һәйәт*[2] *голәмәсе бер җиргә җыйналып шуны тамашага килсенләр!» – димәге кеби бер игъландыр»*[3].

Мәкаләдә тәкъдименең кабул ителмәвен үзенчә аңлатып, Муса әфәнде көйсезләнгән галим-голәмәне мондый сүзләр белән фаш итә: «*Соң көнләрдәге һөҗүмләрендән хәлнең хакыйкате мәгълүм улды: дәгъвәт улынмыш имамлар арасында мәсьәлә гыйльмияне мөзәкәра идә белер кадәр әһлияте*[4] *бар имамларның юклыгы тәмам күренде. Уйлә*[5] *имамлар илә мәҗлесдә иҗтимагдан*[6] *бер файда улмазлыгы аңлашылды. Буңа күрә дә мәҗлес дәгъвәт итмәк хосусында ысрарымдан*[7] *кайттым. Бундан соң мәсьәләйи матбугат галәмендә әһелләрейлә мөзәкәра итмәк кифайә идәр»*[8].

Мәкаләсен Муса әфәнде мондый сүзләр белән тәмамлый: «*Журналларның берендә һәммә имамларның имзасы илә бәнем көферемә фәтва язылмыш исә, зәррә кадәр тәәссеф итмәдем*[9]*. Гыйльми бер мәсьәләдә һәрбер уфак хәрәкәтләрдән утанмаз*[10] *имамлар илә бер мәҗлес гыйльмидә иҗтимаг итмийә рагъбәт итмеш идем. Иштә*[11] *тәәссефем ялңыз шу нокта үзәрендәдер. Аллаһның гавене*[12] *илә мәсьәләйи*

[1] нәмунә – үрнәк.

[2] фән-е һәйәт – астрономия.

[3] Муса әфәнденең дәгъвәте хакында. // Вакыт. 1909. № 554.

[4] әһлият – булдыклылык; белемнең җитәрлек булуы.

[5] уйлә – андый.

[6] иҗтимаг – җыелышу.

[7] ысрар – үз сүзендә тору; башлаган эшне җиренә җиткерергә теләү.

[8] кифайә идәр – җитәр; җитә калыр.

[9] тәәссеф итмәдем – кәефсезләнмәдем, күңелсезләнмәдем.

[10] утанмаз – оялмас; ояла белмәгән.

[11] иштә – менә; нәкъ бу; нәкъ шушы.

[12] гавен – ярдәм.

*тәфсилләре илә «Шура» сәхифәләрендә язарым. Ләкин уйлә һөҗүмләрә бундан соң аслән илтифат*[1] *идәмәм*»[2].

Югарыда бәян ителгән чыганаклардан аңлашылганча, Муса әфәнде кара көчләрнең аңа каршы башлаган һөҗүменнән куркып калмый. Ул, киресенчә, Аллаһ мәрхәмәтенең табигатенә кагылышлы үзенең идеяләрен алга таба да таратуны, халыкка тәфсилләп аңлатып җиткерүне максат итеп куя. Бу очракта сүз милли матбугат сәхифәләрендә бастырып чыгарган мәкаләләре генә түгел, халык белән очрашулар турында да бара. Мәсәлән, «Вакыт» гәзитенең 29 декабрь санында «*Мөселман җәмгыятендә уку мәҗлесе*» исемле мәкаләнең хәбәр итүенә күрә, декабрьнең 27 сендә кичкырын Мөселман җәмгыятендә аеруча күп кеше җыелган була, чөнки халык арасында мәҗлескә Муса әфәнденең дә килеп чыгыш ясаячагы турында хәбәр тарала. Муса әфәнде белән бик күпләрнең кызыксынуы мәҗлескә 600 дән артык кеше килүеннән бик яхшы күренә. Анда да, урын җитмәү сәбәпле, күпләр кире киткәннәр. Бу мәҗлестә чыгыш ясаганда Муса әфәнде, шул исәптән, үзенең мәдрәсәдән китү сәбәпләренә ачыклык кертә һәм, эшен дәвам итәргә чакырылган булуына карамастан, анда кире әйләнеп кайтмаячагын белдерә.

Бигиевне яратып өлгереп, аның өчен җаннарын фида кыйлырга әзер булган шәкертләр һәм мөгаллимнәрнең байтагы аның мәдрәсәдән китүенә кискен ризасызлыкларын белдерәләр – мәдрәсә мөтәвәлиләренә күпсанлы протест хатлары ява башлый. Нәтиҗәдә, 1909 елның 21 декабрендә мәрхүм Әхмәт бай Хөсәеновның вакыфын багучы мөтәвәлиләр җыелышы үткәрелә. Җыелышта шәкертләр һәм мөгаллимнәр тарафыннан Муса әфәндене мөгаллимлеккә кире кайтаруны таләп итеп язылган хатлар карала. Ахыр чиктә, мәсьәлә тавышка куела һәм унике мөтәвәлинең тугызы Бигиев таләпләрен канәгатьләндерергә ризалыкларын белдереп, гаризасын кире алуын үтенү кирәклеге турында карар итәләр. Бу карарны мәдрәсә ректоры Муса әфәндегә тапшыра, әмма

[1] илтифат – игътибар.

[2] Муса Бигиев. Иң ахыр сүзем. // Вакыт. 1909. № 556.

ул мөтәвәлиләр үтенечен кабул итми, 1910 елның февраль ае башында Оренбургтан бөтенләйгә китеп бара. Бу хакта хәбәр иткән «Вакыт» мәкаләсе мондый сүзләр белән тәмамлана: «*Муса әфәнде мәдрәсәдә атнага утыз сәгать иң мөһим дәресләр укытмакта иде. Әгәр ул истигъфасыны кире алмаса, шәкертләрнең хәле тагын мөшкел каладыр*»[1].

Бигиевнең милли вакытлы матбугат сәхифәләренә чыккан һәм соңрак госманлы матбугаты тарафыннан да игътибарга алынган дәгъвасы мөселман җәмәгатьчелеген икегә – «Хөсәения» мөдәррисенең акылга сыймаслык идеяләренә фанатикларча ярсып каршы чыккан күпчелек, һәм ул идеяләрне байрак кебек күтәреп алган азчылыкка – бүленә. Югарыда искә алынган бүленештән олпат могътәбәр затларыбыз да читтә калмаган. Мәсәлән, Бигиевнең дәгъвасын иронияле көлкегә алып, милли шагыйребез Габдулла әфәнде Тукай «*Зур бәшарәт*» *(*«*Рәхмәте илаһия гомуми*»*)* исемле шигырен язган:

*Бәшарәт сезгә, и әһле Петербург!*
*Шулай ук сезгә дә, әһле Нью-Йорк!*
*Бәшарәт сезгә дә, и Берлин әһле!*
*Шулай ук сезгә шатлык, Лондон әһле!*
*Бәшарәт сезгә дә, карсак японнар!*
*Бәшарәт сезгә, чиннәр һәм дә финнәр!*
*Беләмсез, калмыйсыз сез утта мәңге,* –
*Алыр сезне йолып Муса әфәнде!*

Татар матбугатында кызу полемик бәхәсләр кузгатып җибәргән мәсьәләне Исмәгыйль ага Гаспринский[2] да игътибарына ала һәм үзенең «Тәрҗеман»[3] гәзитендә, уены белән ар-

[1] Мөтәвәлиләр мәҗлесе // Вакыт. 1909. № 559.

[2] Исмәгыйль Гаспринский (Мостафа углы Исмәгыйль Гаспралы / Бөек остаз; 1851–1914) – чыгышы белән Кырым татарларыннан булган җәмәгать эшлеклесе, ысул-ы җәдид (яңа ысул) методикасына һәм җәдитчелеккә нигез салган күренекле педагог, әдип, төрки халыкларның мәдәни, рухи берлеге идеясен алга сөргән фикер иясе, «Тәрҗеман» гәзитенә нигез салучы нашир, журналист һәм публицист.

[3] «Тәрҗеман» (тулы исеме «Тәрҗеман-Переводчикъ») – 1883–1918 елларда Бакчасарайда (Кырым) чыккан беренче гомумтөрки

тык мавыгып киткән балага бармак белән янаучы бер агай сыман, Бигиевне юк-бар белән шөгыльләнүче саташкан философ итеп күрсәтүдән тартынмыйча, мондый сүзләр язган: «*...әгәр Муса әфәнденең бирдеге дәресләрендә Әхмәд Мидхәт*[1] *әфәнденең Истанбул дарелфөнүнендә дәрес итдеге тарих-ы әдъйанны раһбәр*[2] *тотмыш улса иде, нафигъ*[3] *вә мөәссир*[4] *бер хезмәт итмеш булырды. Истанбул таләбәсенә*[5] *кяфи улыр*[6] *дәресләр Ырынбург җәмәгатенә дә аз улмазды… Руслар бер заман гакыллардан әман*[7] *буламыеп*[8]*, «гакылдан бәла» мәкалене чыкармышлар иде; Әлхәмделиллаһ! Бәзем гакыл күплегендән шикәятькә чыкмак йуктыр, фәкать философ шукадәр чугалды*[9] *ки, «фәлсәфә бәласе» мәкаленә чыкмак бардыр*»[10].

Татар милли мәгарифендә тирән һәм бәрәкәтле эз калдырган галим Һади әфәнде Максуди[11] дә дәшми калмый. Муса әфәнденең Аллаһ мәрхәмәтенең табигатенә кагылышлы фикер вә карашларын таный алмыйча, никадәр ярсу хисләр кичергән булуы аның «Тик тора алмыйм» дип аталган мәкаләнең исеменнән үк сизелеп тора. Ул мәкаләсен мәзәксыман бер кереш белән башлап җибәрә: «*Мулла вәгазь сөйли:*

---

газета. Гәзиткә нигез салучы һәм нәшер итүче кырым-татар мәгърифәтчесе Исмәгыйль Гаспринский (1851–1914) була.

[1] Әхмәд Мидхәт (1844–1912) – Госманлы Дәүләти Галиясендә иҗат иткән язучы, журналист, нашир, тәрҗемәче.

[2] раһбәр – әйдәп баручы, юлбашчы.

[3] нафигъ – файдалы; файда китерүче.

[4] мөәссир – тәэсирле; тәэсир итүче.

[5] таләбә – шәкертләр.

[6] кяфи улыр – җитәрлек; җитә торган.

[7] әман – тынычлык, иминлек.

[8] буламыеп – таба алмыйча.

[9] чугалды – ишәйде, күбәйде.

[10] Гаспринский И. «Тарих-ы әдъйан вә исабәт» // Тәрҗеман. 1909. 25 декабрь. № 52.

[11] Һади Максуди (Низаметдин углы Әхмәт-Һадый Максудов; 1868–1941) – күренекле җәмәгать эшлеклесе, мәгърифәтче, мөгаллим, тел галиме; татар һәм гарәп телләрен укыту өчен күпсанлы дәреслекләр һәм кулланмалар авторы.

*«Һарут-Марут...», дигәч тамак кыра берәү. «Ялгыштым, Йәэҗүҗ-Мәэҗүҗ икән!», – дип дөресли үзен мулла.*

*Муса әфәнде Бигиев тарафындан «Шура»ның 22нче нумирына «Тарих-ы әдъйан дәресләре» сәрләүхәле озын бер бәнд*[1] *язылган иде. Менә шул бәндгә әлеге «Эһһем!» (тамак кыру) диюче мужик кебек, мин дә тамак кырмакчы булам вә язачак нәрсәләремә мөкаддимә сурәтендә буйлә берәр җөмлә дә язарга уйлаб дияем...».*

Бу сүзләрдән соң Һади әфәнде, Көнбатыш фәлсәфәчеләре Штейнер[2], Фейербах[3], Штраус[4], Бюхнер[5] кебекләрнең дингә һәм илаһка карата әйтелгән фикерләреннән өземтәләр китереп, философларга ни әйтсәләр дә ярый дип җөпләп куя һәм болай дип дәвам итә: «*Әмма Муса әфәнде бәндене мөселман булып язды... Муса әфәнде үзенең язган сүзләрен философ булып кына язган булса иде, без дә аның сүзенә шимди*[6] *мөкабәлә идәҗәк*[7] *сүзләремез илә мөкабәлә итмиенчә, анҗак*[8] *икенче төрле мөкабәлә идәр идек... Муса әфәнде бу сүзләрен дингә ышанмаган бер философ булып язмаенча, бәлки мөселман булып язар!... Шул сүзләрне Коръән илә тәтбикъ идәм*[9] *хыялы нәчаклы көлке вә нәчаклы әсассез*[10] *исә, Муса әфәндең һәм «бөтен инсанларның кыяматтә нәҗаты*[11]*» дигән*

---

[1] бәнд – язма, мәкалә.

[2] Штейнер (Рудольф Штейнер; 1861–1925) – австрияле фәлсәфә докторы, педагог, мәгърифәтче, эзотерикачы, күпсанлы китаплар; антропософиягә нигез салучы.

[3] Фейербах (Людвиг Андреас фон Фейербах; 1804–1872) – алманияле фәлсәфәче, дәһри.

[4] Штраус (Давид Фридрих Штраус; 1808–1874) – алманияле дин галиме.

[5] Бюхнер (Людвиг Бюхнер; 1824–1899) – алманияле табиб, фән эшлеклесе, фәлсәфәче.

[6] шимди – хәзер; шушы мәлдә.

[7] мөкабәлә идәҗәк – каршы торачак; каршылык күрсәтәчәк.

[8] анҗак – тик, фәкать.

[9] тәтбикъ идәм – дәлиллим, раслыйм.

[10] әсассез – нигезсез.

[11] нәҗат – коткарылу.

*фикерене Коръәнгә тәтбикы шулчаклы көлке вә шулчаклы әсассездер»*.

Мәкаләсенең дәвамында Һади әфәнде ислам диненең сафлыгы югалуы сәбәбен аның мәзһәбләргә бүлгәләнүе аркасында булганына инануын белдерә, Аурупаны куып җитәр өчен Коръәннән ерагаясы түгел, киресенчә, аңа мөмкин кадәр якынаерга кирәклеге турында әйтә һәм, үзенең ни мөтәкәллим, ни әшгаричы, ни мөгътәзиләче булмавын ассызыклаганнан соң, үзен «мин чын Коръәнче» дип атый да, Муса әфәндегә Коръән аятьләре белән җавап бирергә ниятләве турында игълан ясый[1].

Исемнәре халыкка мәгълүм булган олпат затлар бер якта торсын, даннары җитәкләгән мәхәлләдән ары китмәгән муллаларның Муса әфәндегә каршы чыкканнарын санап бетергесез. Бу юнәлештә лаф оручылар өчен Оренбург Дини нәзарәте каршындагы «Дин вә мәгыйшәт» журналының сәхифәләре менә дигән гайбәт чаты булып китә – 1910 елның беренче дүрт ае дәвамында гына аена ике мәртәбә чыга торган бу журналның сәхифәләрендә ярсу вә нәфрәт белән чәчрәп торган кырыктан артык мәкалә басыла. Шундый мәкаләләрнең берсендә байтак кына имамнарның имзалары белән күмәк протест хаты да дөнья күрә. Ул хатка кул куючылар Муса әфәндене тәкфир кылалар, ягъни диннән чыгып кяфергә әйләнүдә гаеплиләр. Болар – югарыда искә алынган бүленешнең күпчелеген тәшкил итүчеләр.

Мисалга, «Вакыт» гәзитенең 1909 ел 8 декабрь санында имзасыз автор тарафыннан «Муса әфәнденең дәгъвәте хакында» исемле бер мәкалә басыла. Язмада мондый сүзләр бар: «*Муса әфәнде Бигиев 22 нумир «Шура»да үзенең тарих-ы әдъйан дәресләрене яздыгы вакыт рәхмәт илаһиянең гомумиятене идга иткән*[2] *иде. Моны күргәч «Дин вә мәгыйшәт» әһеле кыямәт куптардылар, үзләренчә рәддияләрене*[3] *яздылар,*

[1] Һади. Тик тора алмыйм // Шура. 1909. № 24. Б.756–758.

[2] идга иткән – дәгъва кыйлган, ишеттергән.

[3] рәддия – нинди дә булса китапта бәян ителгәннәрне инкяр итү, кире кагу өчен язылган башка бер китап.

*аны мәдрәсәдән кудырырга кирәк-фәлән, дип кычкырдылар. Туй мәҗлесләрендә дуладылар; пылау кашыгын селти-селти «Дин юлында сугышып шәһид буламыз!» – диделәр; холяса*[1]*: үз кулларындан килгән һәрбер чарага тәшәббес итделәр*[2]*... «мәҗнүн»*[3] *дия атадыклары бер кешенең сүзләре өчен үрле-кырлы сикергән, бәлеш хозурында кашыклар селтәп гөж килгән, «Кәфер дә, көфер дә!», дип кычкырган; «Сөрәмез! Мәдрәсә-и Хөсәениияне таш өстендә таш калмадыкча җимерәмез!» – дип сүгенгән кешеләр, йөз ба йөз килеп мөназара кыйлышырга дәгъвәт ителдекчә менә ничек җаваб бирәләр!! Затән*[4] *бунлардан шундан башка җаваб көтмәк габәсдер*[5]»[6].

Инде Муса әфәнде игълан иткән карашларны хуплап-яклап чыгучылар турында да бер-ике сүз әйтик.

Бу юнәлештә язылып, безгә мәгълүм булган беренче язма – күренекле җәмәгать эшлеклесе Борһан Шәрәфнең[7] «*Мәдәнилеккә имтихан*»[8] исемле мәкаләседер. Шәрәф үзенең мәкаләсен хатирәләрендә сакланган бер әңгәмә белән башлап җибәрә: «*Моннан биш-алты ел элек, мин әле «Мөхәммәдия» шәкерте булган чакта, бер могътәбәр әфәнде, шәкертләрнең фикерләү дәрәҗәләрен ачыклар өчен миңа бер сорау биргән иде. Бу әфәнде Аурупа фәнни традициясе белән һәм андагы рациональлек дәрәҗәсе белән таныш иде. Аның миңа биргән сөале дә мәдрәсәдә өйрәнгән нәрсәләр турында түгел иде... Ул миннән: «Синең кяферләргә карата мөнәсәбәтең ничек? Алар нәҗесме? Мәңгегә җәһәннәм утында калачак мөрдарлармы? Ислам турында бер авыз сүз ишетмәгән француз мужик утта мәңгегә калачакмы? Башкаларга үзенчә игелек кыйлган вә файда китергән алман, инглиз, рус кеше сезнең*

[1] холяса – кыскасы; кыскартып әйткәндә.

[2] тәшәбес иттеләр – керештеләр, алындылар.

[3] мәҗнүн – җенләнгән, тиле, дивана.

[4] затән – чынлыкта; дөресен әйткәндә.

[5] габәс – файдасыз эш.

[6] Муса әфәнденең дәгъвәте хакында // Вакыт, 1909. № 554.

[7] Борһан Шәрәф (Шәрәфетдин углы Борһан Шәрәф; 1883–1942) – дин һәм җәмәгать эшлеклесе, язучы, нашир, педагог.

[8] Шәрәф Б. Мәдәнилеккә имтихан // Вакыт, 1909. № 558.

*китапларны белмәгәне аркасында гына утта калачакмы? Ә бит хәзерге мөселманнар да исламга үз белдекләре белән түгел, әмма тәкъдирнең әмере белән килгәннәр. Олуг галимнәрнең фикеренчә, хәзерге вакытта саф ислам динен тотучы һичкем юк. Болай булганда, исемнәре генә мөселман булып, башкалаларга аз файда китергәннәр мәңгегә рәхәттә калачак, ә күңелләре белән хакыйкатьне эзләгән һәм көчләрен адәм баласы файдасына сарыф иткән формаль кяферләр мәңгегә утта калачаклармыни?» – дип сорады.*

*Мин мондыйрак җавап бирдем: «Ислам диненең хөкеменә күрә, без һичкем турында да «ولا نحكم احد بالجنة ولا بالنار»*[1] *дип әйтә алмыйбыз. Икенче яктан, без адәм баласыны кыйлган игелекнең дә, яманлыкның да юкка чыкмавына ышанабыз. (فَمَن يَعْمَلْ مِثْقَالَ ذَرَّةٍ خَيْرًا يَرَهُ وَمَن يَعْمَلْ مِثْقَالَ ذَرَّةٍ شَرًّا يَرَهُ)*[2]*. Шуңа күрә без Аллаһның рәхмәтен тик мөселманнарга гына хасламыйбыз.*

– Алай булгач, кайбер мәсьәләләрдә хакыйкатьнең мөселман булмаганнар өчен дә ачык булуын сез таныйсыз, димәк? – дип дәвам итте ул.

– Әйе, хакыйкатьнең кайбер мәсьәләләрдә мөселман булмаганнар өчен дә ачык булуына без ышанабыз,– дидем.

– Син генәме шулай уйлыйсың, әллә чордашларының һәммәсе дәме?

– Аларның күпчелеге.

– Болай булса, мин сезне тәбрик итәм! Казан шәкертләре Истанбул һәм Мисыр мәдрәсәләре шәкертләреннән алдынгырак! – дип ул сүзен тәмамлады.

Чыннан да, без Аурупа галимнәренең мөселманнарга карата игелекле мөгамәлә кыйлуларын ишеткәч шатланабыз. Христианнарның мөселманнарга карата кешечә, тигез күреп гамәл кыйлуларын яратабыз. Болай итүләре аларның мәдәнилекләрен күрсәтә. Әмма бу безнең дә башкаларга карата шундый булырга тиеш булуыбызны белдермиме? Әгәр без

[1] Тәрҗемәсе: «Һичкем турында: «Җәннәттәдер» дип вә яки «Җәһәннәмдәдер» дип хөкем кыйлмагыз».

[2] «Тузан бөртеге кадәр игелек кыйлучы күрер аны, һәм тузан бөртеге кадәр яманлык кыйлучы күрер аны» (Коръән, 99:7–8).

аларны кимсетсәк, димәк безнең алар белән мөнәсәбәтләребез йә бик начар, йә үз файдабыз өчен генә булачак. Боларның икесе дә бик яман.

*Муса әфәнде күтәргән мәсьәлә мәдәнилек күзлегеннән караганда ифрат та әһәмиятледер. Безне мондый фикерләргә китергән тәрәккъыятебез безгә мәдәният галәменә кушылырга юл ача. Галимнәребезнең берсе тарафыннан әлеге мәсьәләнең куелуы исә безгә мәдәният галәменә кушылу хакына ия булу өчен бер дәгъвадыр...*»[1].

1909 елның 14 декабрендә «Шура» журналында Шәкки[2] исеме астында берәүнең Муса әфәндене хуплап язган мәкаләсе басыла: «*«Шура»ны бик мөхтәрәм бер каләм тәзъйингә башлаган*[3]*. Бундан дулайы «Шура» кариләрене тәбрик идәрем. «Тарих-ы әдъйан», «Гыйлем-е рух» дәресләре «Шура» шәкертләренә бик күп файда бирәчәктер*».

Шундый канатландыручы сүзләрдән соң автор диннәр тарихының әүвәлдә укытылышының җитешсезлекләренә кагылып уза: «*Ләкин «Тарих-ы әдъйан» нәкадәр битарафанә язылыр вә укытылыр исә, шулкадәр файда вирер... «Тарих -ы әдъйан» дәресләрендә ул битарафлыкны була алмадым*[4]*. Тәэвилләр, тәфсирләр киләчәктә дәхи*[5] *бик күп тәэвил вә тәфсиргә юл ачачакны күрсәтә. Әхмәд Мидхәт әфәнде дәхи Истанбул дарелфөнүнендә «тарих-ы әдъйан» дәресләрене*

[1] Шәрәф Б. Мәдәнилеккә имтихан // Вакыт. 1909. № 558. (хәзерге татар теленә тәрҗемә).

[2] Шәкки – бу тәхәллүс астында Ага-оглу Әхмәдбәк Мирза Гасанбәк-оглу (1869–1939) исемле күренекле публицист, мәгърифәтче, әдип, педагог, галим һәм җәмәгать эшлеклесе язган. Париж Хокук мәктәбен һәм Сорбонна университетын тәмамлый. 1905–1909 елларда Азәрбайҗанда милли азатлык хәрәкәтенең актив катнашучысы. 1909 елда Төркиягә күчеп китә, дәүләт хезмәтендә югары вазифаларда хезмәт итә, Истанбул һәм Әнкара университетларында лекцияләр укый, 1920–1935 елларда чыккан «Хакимият-е миллия» сәяси гәзитенең баш мөхәррире.

[3] тәзъйингә башлаган – бизи башлаган.

[4] була алмадым – таба алмадым.

[5] дәхи – тагын, тагын да.

*шулай укытырга башлагандан «тарих-ы әдъйанның» эчендән чыга алмады... Истанбул дарелфөнүнендә, Ырынбырг мәдрәсәсендә тарих-ы әдъйан укыту мәсьәләсе Төркиядә хөррият илә узак горбәттә[1] булынган иске фикерләрнең мәгълүбиятене[2] күрсәтә. Буның өчен дәхи, мәдрәсәи Хөсәения шәкертләрене чын күңелдән тәбрик идәрем»*[3].

Матбугат сәхифәләрендә Муса әфәнденең фикерләрен яклап чыккан мәкаләләр арасында Әхмәт-Һади Максудиның инде искә алынган язмасына да игътибар итүчеләр була. Андыйларның берсе Ризаэтдин хәзрәт тарафыннан язылып, халыкка мондый сүзләр җиткерә: «*Фазыйләт-е имам вә мөдәррис Һади әфәнде хәзрәтләре! «Тик тора алмыйм» гонваны илә язылмыш мәкаләңез тәклифеңезә күрә, 24 гадәд «Шура»да басылды... фәкать бер кемсә тарафындан ачылмыш бәхәс ахырына барып җитмәстән элек аның каршысына төшмәк вә сөйләмәктә улан сүзене кисмәк хакында бөтен дөнья халкы тик тора алмадыклары вакытта да сезнең тик торып та нәтиҗәне көтәчәкеңездән әмин идек*[4], *зира әдәб вә тәрбия, акыл вә шәригать буны икътиза итсә кирәк*[5]. *(...)*

*«Шура» гыйльми бәхәсләр вә галимләрнең каләмләре өчен мәйдан улдыгындан һәрнәкадәр кәнди*[6] *фикеремезә муафыйк дәгел*[7] *исә дә, Муса әфәнде бәхесенә*[8] *урын бирдек. Ошбу гыйлем гасырында чыкмакта булган бер мәҗмуганың ялңыз бәнем игътикадым вә бәнем фикеремә тәбигъ тотылмасы*[9], *әлбәттә, мөмкин дәгел. Ушандак*[10] *гыйльми вә әдәби улмак шарты илә Муса әфәнде бәхесенә каршы улан рәддияләр дә,*

---

[1] узак горбәттә – еракта.
[2] мәгълүбият – җиңелү, җиңелгән булу.
[3] Шәкки // Шура. 1910. № 2.
[4] әмин идек – ышана идек.
[5] икътиза итсә кирәк – таләп итә булса кирәк.
[6] кәнди – үз.
[7] муафыйк дәгел – туры килми торган.
[8] бәхес – тикшеренү.
[9] тәбигъ тотылмасы – иярүе, туры килүе.
[10] ушандак – шундый.

*әгәр дә килерләр, исә, дәреҗ улыныр*[1]*, фәкать бүгеннән дәгел, бәлки Муса әфәнде бәхесе тәмам улдыгындан соң!. «Шура» мөхәррире Ризаэтдин Фәхретдин*»[2].

Риза хәзрәт Бигиев дәресләрен «Шура»ның берничә санында бастыру, татар матбугатында әлеге мәсьәләгә кагылышлы күтәрелгән полемикада актив катнашу белән генә чикләнмәгән. Мәсьәләнең үтә дә әһәмиятле иҗтимагый проблема булуын аңлату һәм, аңа ачыклык кертеп, халыкны агарту, белемле итү өчен, 1910 елда тулысынча илаһи мәрхәмәт мәсьәләсенә багышланган «*Рәхмәт илаһия мәсьәләсе*» («Илаһи мәрхәмәт мәсьәләсе») исемле китап язып дөньяга чыгара.

Муса әфәнденең идеяләре тәэсирендә купкан матбугат туфанына Госманлы Дәүләт-и Галиясенең матбугаты да кушылып китә. Биредә Муса әфәнденең карашларын яклап чыгучылар да, кискен сурәттә тәнкыйть итүчеләр дә була. Мәсәлән, Истанбулда чыгып килгән «Түрк Йурду» исемле журнал[3] татар галимен хуплап мондый сүзләр язган: «*Ниһаять, Русиядә үзенең китаплары илә дан казанган зур галим пәйда булды. Ул галим – Муса Җаруллаһ. Аның исламны чынлап яңартучы булуында бер генә дә шик юк*».

1909 елда Муса әфәнде хәдис гыйлеменә багышланган «***Әл-Моваттаъ***» исемле китап бастыра. «Шура» журналына бу китап турында түбәндәге хәбәр бирелгән: «*Гыйлеме*

---

[1] дәреҗ улыныр – бастырылыр; нәшер ителер.

[2] Фәхреддин Р. Ырынбург шәһәреннән Бөгелмә өязеннән «Әлмәт» карьясеннән // Вакыт. 1909. № 554.

[3] «Түрк йурду» («Төрек йорты») – 1911 елның 30 ноябреннән 1918 елның 15 июленә кадәр Истанбулда айга ике мәртәбә чыгып килгән 32 сәхифәле гомумтөрки миллиятчел рухлы журнал. Журнал нәшер ителгән җиде ел дәвамында аның 161 санын үз эченә алган 14 җилде (тупламы) дөнья күрә. 1 нче, 2 нче җилдләр һәм янә, 5-нче җилдтән дәвам итеп, 12 нче җилдкә кадәр журналны җәваплы сәркятиб вазифаларын башкарган Йосыф әфәнде Акчура (1876–1935) чыгара. 1918 елда чыгышы тукталган журнал кабат 1923–1931 елларда, 1943, 1954–1957 елларда, 1959–1968, 1970, 1987–2001 елларда нәшер ителеп тора. 1989 елдан бүгенгәчә Әнкарада нәшер ителә.

*хәдистә мәшһүр китапларның бере, имам Малик хәзрәтләре*[1] *тарафыннан тәэлиф ителмеш*[2] *«Әл-Моваттаъ» идеге хәтта ки Бохари вә Мөслим «Сахих»лары*[3] *дөньяга чыкмастан, мөкаддәм*[4] *Коръән Шәриф соңында*[5] *игътимады*[6] *вә дөрест булган китап та «Әл-Моваттаъ»дыр, дип сөйләндеге мәшһүрдер. Иштә*[7] *ошбу китапның кәнди*[8] *шәкерте булган имам Мөхәммәд*[9] *риваять итдеге нөсхәсе бу көннәрдә Казан шәһәрендә «Мәгариф» китапханәсе» харәҗәте*[10] *илә тәбгы булынырга башландыгы идарәбезгә килмеш беренче формасыннан мәгълүм булды. «Әл-Моваттаъ» баблары хәнәфи мәзһәбендә булган фикъһы китапларының баблары тәртибендә язылдыгыннан һәм дә мәзһәбендә бөек бер мөҗтәһид исеменә мәнсуб*[11] *булдыгыннан Русия исламнарыны*[12] *хәдис гыйлеменә җәлеб әйләргә васита*[13] *булачагы өметледер. Ошбу ноктадан «Мәгариф» хәдис китабы бастырмак хакында*

---

[1] имам Малик (Әбу Габдуллаһ Малик ибне Әнәс әл-Әсбахи, миләди 712–795) – дин галиме, фәкыйһ, мөхәддис, хронология буенча икенче булган мәлики фикъһы мәзһәбенә нигез салучы. Имам Маликның Әмир исемле бабасы Мөхәммәт пәйгамбәрнең сәхабәсе булган.

[2] тәэлиф ителмеш – язылган.

[3] «Сахих» («Сахих әл-Бохари», «Сахих Мөслим») – хәдис җыентыкларының бер төре. Сахих сүзе «ышанычлы» мәгънәсендә булып, җыентыкка кертелгән хәдисләрнең шул сыйфатын алга сөрә.

[4] дөньяга чыкмастан мөкаддәм – дөньяга чыкканчы.

[5] Коръән Шәриф соңында – дәрәҗәсе буенча Коръән Шәрифтән соң икенче булып торучы.

[6] игътимад – таяну; ышанычлы чыганакка нигезләнү.

[7] иштә – менә; шулай итеп.

[8] кәнди – үз; үзе; үзенеке.

[9] Имам Мөхәммәд (Мөхаммәд бине Йахъя әл-Әнсари) – имам Маликның остазы.

[10] харәҗәт – матди чыгымнар.

[11] мәнсуб – бәйле булган; караган.

[12] исламнар – мөселманнар.

[13] васита – чара.

*мәзкүр әсәрне интихаб итмәгендә[1] исабәт әйләмешдер[2]. Халыклар ошбу әсәр илә гомуми сурәттә өлфәт[3] пәйда итсәләр, Көтеб ситтә[4] вә хосусан «Сахих»ларын[5] да истигъмаль итәргә[6] мәҗбүр булачактыр. Фәкать бу әсәр, имам Мөхәммәдтән башка китаплары рәвешендә игътимадлы сурәттә нәкыль иделмешмедер[7]? Бу мәсьәлә, безләргә һәнүз[8] мәгълүм булмады[9]»*[10].

## Гыйлеме һәйәт, ягъни астрономиягә караган хезмәте

Шулай ук 1909 елда Муса әфәнденең «***Шәригать ничүн роэйәти[11] игътибар итмеш?***»[12] («Шәригать нидән яңа туган ай күренүен игътибарга алган?») исемле фәнни хезмәте дөнья күрә. «Шура» журналы бу китап турында мондый белдерү ясаган: «*Фазыйл мөхтәрәм Муса әфәнде Бигиев тарафындан каләмә алынуб да «Шәрык» китабханәсе тарафындан нәшер иделмеш ошбу рисалә исемемезгә һәдия уларак кил-*

[1] интихаб итмәгендә – сайлап алуында.

[2] исабәт әйләмешдер – дөрес иткән, дөрес эшләгән; дөреслеккә ирешкән.

[3] өлфәт – дуслык, үзара килешү.

[4] Көтеб ситтә – ислам дөньясында иң танылган һәм иң абруйлы алты хәдис җыентыгы, шул исәптән – имам Бохари белән имам Маликның «Сахих»лары.

[5] «Сахих»лар (сахих: яхшы, ышанычка лаеклы; дөрес) – ышанычлы хәдисләр җыентыклары.

[6] истигъмаль итәргә – кулланырга, файдаланырга.

[7] нәкыль иделмеш – тапшырылган.

[8] һәнүз – әле, әлегә.

[9] Имам Маликның «Әл-Моваттаъ» исемле хәдисләр җыентыгы ул заман гадәтенчә бер равидан (тапшыручыдан) икенче равига колактан колакка тапшырылып килгән. Шул рәвешле аны тапшыручылар саны байтак: Мәдинәдән – 17 рави, Мәккәдән – 2, Мисырдан – 10, Гыйрактан – 27 һәм башкалар. Мәкаләнең ахырындагы сорау шуны күздә тота.

[10] Китабу әл-Моваттаъ // Шура. № 13, 1909.

[11] роэйәт (роэят) – күктә яңа айның күренүе.

[12] Муса Бигиев. Шәригать ничүн роэйәти игътибар итмеш? Казан: Әхмәд – әл-Исхакый, 1910. 110 б.

*де. Исемендән хас бер шәйдән бәхәс иделдеге аңлашылса да, мөндәриҗәсе гомуми улуб пәк күб шәйләрдән бәхәс иделмешдер. Гыйлми вә фәнни улан бу әсәр үзенең әрбабы ичүн зийадә файдалы улса кирәк. Һәрбер мәшһүр китабчыларда улынур. Хакы 30 тиендер*».

Әлеге белдерүне язучы китапның эчтәлеге турында тагын бер-ике җөмлә өстәүдән гаҗиз калган булса кирәк, чөнки чынлыкта шактый күләмле бу китап тулы мәгънәдә бер энциклопедиягә тиң: аның сәхифәләрендә кешелек дөньясы тарихында ел исәбе төрләре, төрле календарьлар темасыннан башлап, һәртөрле үлчәм микъдарлары, күк җисемнәренең хәрәкәтләре, Җир шарының географиясе, Кояш системасының төзелеше, ай вә кояш тотылуының сәбәпләре вә бу хәлләрнең диндә һәм шәригатьтә чагылышлары турында, Мөхәммәт пәйгамбәрнең тәрҗемәи хәленә караган кайбер мөһим вакыйгаларның төгәл даталарын исәпләп чыгару, кыскасы – бихисап мәгълүмат бирелә. Китапның эчтәлеге турында автор болай язган: «*Бу рисаләдә «Шәригать ни өчен роэйәтне игътибарга алган?» мәсьәләсенә җавап бирү максаты белән, елларның, айларның хисаплары, һәм дә әһле гыйлем кашында кабул булып мәшһүр булган календарьларның тәртипләре бәян кыйлынмыштыр. Иң ышанычлы сурәттә ай елларының башларын табу өчен бер төгәл кагыйдә китерелеп, «әһҗәз дәбүд» кагыйдәсе дә искә алынды. Исәпләүне җиңеләйтү өчен вакланма*[1] *унарлы вакланма сурәтендә кулланылып, саннарда хаталанмас өчен дә һәрбер мөһим саннар бер мәртәбә исемнәре белән теркәлде.*

*Көннәр, айлар, сәнәләр хакында Коръән кәримдә китерелгән айәт кәримәләр зикер ителеп, «шәригать исламия кояш елларын игътибарга аламы?» мәсьәләсенә караган уйларымны китергәннән соң, исламда кояш ел исәбе тарихы хакында бер-ике сүз әйтелде.*

---

[1] вакланма (кәсер) – биредә исәпләгәндә тулы саннан (бөтеннән) калган өлешләр күздә тотыла.

*Астрономнарның хисабы роэйәт кебек могътәбәрме? Юкмы? мәсьәләсендә фәкыйһларның сүзләре китерелеп, бу хакта Шаригъның*[1] *карашы да бәян ителде.*

*Иң азакта, тагын бер файда арттыру өмете белән, шәригатьтә кулланылган микъдарлар турында фәкыйһларның төрле сүзләрене килештерү юлында ясалмалылыктан ару булган бер-ике сүз сөйләнмештер».*

Бу өзектә телгә алынган саннар китапта очраклы сурәттә генә очрамыйлар. Аның зур өлеше хисаплауга багышланып, әсәрне математик бер кулланмага охшата. Мисал өчен ел озынлыгын исәпләп чыгаруга багышланган бер өзек китерик: «*Күбрәк расыдларның, галә-л-хосус Морза Олуг Бәк хәзрәтләренең тәхкыйкатенә күрә, бер сәнә микъдары – ягъни Көррә-и арызның үз мәдарендә кояш әтрафында бербөтен дәүрәсе – (365) өч йөз алтмыш биш көн, (5) биш сәгать, (49) кырык тугыз дакыйка, (24,1) йекерме дүрт бер гошрә сания.*

*365 дан фазлә кәсерләри санияләрә тәхвил идүб, у санияләри дә кәсер әгъшарийә тәхвил итмәк ичүн бер көннең санияләренә тәкъсим идәр исәк, 0,24264 хасил улур. Ягъни сыфыр сахыйх йекерме дүрт йекерме алты, дүрт.*

*Уйлә исә, мирза Олуг Бәк хәзрәтләренең хисабына күрә, бер сәнә = 365,24264 көндән гыйбарәт улур.*

*Ягъни өч йөз алтмыш биш көн, һәм дә бер көннең йөзбиң кисәгендән егерме дүрт биҗ ике йөз алтмыш дүрт кимәк.*

*Йаурупа хөкәмасенең тәхкыйкать сахыйхасына күрә бер сәнә (365) өч йөз алтмыш биш көн, (5) биш сәгать, (48) кырык сикез дакыйка, (47) кырык йиде саниядер.*

*Шу кәсерләри кәсер игъшарийә тәхвил идәр исәк, 0.24221 көн хасил улур. (йекерме дүрт, йекреме ике, бер) шу хисаба күрә, бер сәнә = 365,24221 көн улур.*

*(өчйөз алтмыш биш көн, йөз биҗдән йекерме дүрт биң икейөз йекерме бер кисәк.)*

---

[1] Шаригъ (шәригатьче, ягъни шаригать кануннарын гамәлгә куючы) – контекстка күрә йә Аллаһ тәгалә, йә Мөхәммәт пәйгамбәр күздә тотыла.

*Бәгъзы әһле һәйәтнең хисабына күрә, сәнә (365) өч йөз алтмыш биш көн, (5) биш сәгать (48) кырык сикез дакыйка (50,92) илле сахыйх туксан ике кәсер игъшари саниядер. Буңа бинаән:*

*Бер сәнә = 365,242256 көн улур (өч йөз алтмыш биш сахыйх, дүрт йөз кырык ике биң ике йөз илле алты кәмер игъшари.)*

*Расыд хисабыйлә сәнә-и хакыйкыйя шу өч микъдарның берендән гыйбарәт исә дә, иске замандан бире сәнә хисаблары мөхталиф ула килмешдер.*

*Иске мисрыйлар бер сәнәйи һәрбере (30) утыз көнлек (12) унике айдан, 360 көндән гыйбарәт кыйлурлар иде. У вакыт сәнә-и мисрыйә сәнә-и хакыйкыядән һәр дәфга 5,24221 көн кадәр мөкаддәм тәмам улуб, игътидаль рабигый көне һәр дәфга 5,24221 көн кадәр тәэхир идәр торур иде. Тәкърибән 18 сәнә имтидадында яз фасылы кыш мәүсименә интикаль идүб, җәй фасылы тәмамән яз мәүсименә тәхвил идәр иде. 70 сәнә имтидадында игътидаль рабигый көне дүрт фасылның һәрберене дәвер итмеш улур иде.*

*Мөаххиран мисрыйлар сәнәйи 365 көндән гыйбарәт итделәр. Буныңлә мөкаддәмге хаталар беркадәр тәдариек улынды. Ләкин сәнә мисрыя сәнә хакыйкыядән 0,24221 көн кадәр кыйсакалуб тәкърибән һәр дүрт сәнәдә игътидаль көне бер көн кадәр тәаххер идәр иде. (дүрт сәнәдә = 0,24221 х 4=0,96884 көн.)*

*Сәнәләр шу низамлә хисаб улынурса, 365 сәнә ниһаятендә яз мәүсиме кыш фасылы мәхәлленә хөлүл идүб, җәй мәүсиме тәмамән яз мәхәлленә килүр. Мәүсимләрнең үз хәлләренә кайтулары ичүн 1460 сәнә мөддәт лязем улур.*

*Шуңа күрә мисрыйлар бер сәнәйи 365 көн игътибар идүб, 1460 сәнә кадәр мөддәти дә бер «дүрт там» игътибар итмешләр иде.*

*Димәк мисрыйларның шу низамларында һаман ике хэлал калмыш иде: бере тәкърибән бер робыгдан (0,242221) гыйбарәт улан кәсери тәмамән иһмаль итмәк; икенчесе шу иһмаль сәбәбейлә мәүсимләрнең мәхәлләри интикаль итмәк. Мәүсимләрнең үинтикале исә бер тарафдан табигатьнең аһангенә рәвешенә*

*мөхаләфәти ийҗаб идәр, дигәр тарафдан кыш көнләрендә җәй мәүсиме хөлүле кеби мөнәсәбәтсезлеги лязем идәр*».

Муса әфәнденең ел исәбе, астрономия, күк җисемнәренең хәрәкәтләре кебек үзара бәйләнешле темалар белән кызыксынуының гамәли чагылышы булган. Мәсәлән, 1932 ел ахырында ул Финляндиядәге татарлар өчен рамазан ае җәдвәлен (календарен) төзеп бирә. Бу турыда аның хатларыннан укып белә алабыз: «*Рамазан җәдвәлегезне әзерләдем. Расадханә*[1] *мәгълүматына да шатландым. Роэйәт дәрәҗәләренә һөлүл*[2] *шарттыр. Могътәбәр булса һөлүлнең горубдан*[3] *алда булу шарты да бар. Төн алдан килә. 27 декабрьдә зәвәлдән соң сәгать бере егерме ике дакыйка төн берләшмә вакыйг булса, горубдан элек роэйәт дәрәҗәсенә һөлүл күбесенчә вакыйг булмый. Иң элек, Коръәндә төн мөкаддәмдер. Бу тәкъдирдә рамазанның беренче көне 29 декабрь пәнҗешәнбе көнедер.*

*Күк җисемнәренең хәрәкәте һәрникадәр гаять табигый вә монтазам исә дә, айларның вә елларның башлары игътибары горфидер. Сезнең 28нче декабрегезне мин 29ы итә алмыйм. Ул фәкать 28 булып калыр. Хисапта истыйляхымны бәян итү юлында сезгә бу юлларымны яздым.*

*Шәгъбанны ничә көннән исәпләдегез? Дини җәдвәлдә шәгъбанны һәр заман 29дан исәпләү, пәйгамбәр әфәндебезнең горефләренә кайчак каршы килә ала.* (صومكم يوم يصومون وفطركم يوم يفطرون)[4] *сүзеннән максат та бары тик иттифактыр. Бөтен ислам дөньясында булмаса да, иң азыннан бер дәүләттә рамазан вә бәйрәм хакында каршылыклар, әлбәттә, хәрамдер. Басылган җәдвәлне якын арада җибәрермен*»[5].

Гыйлеме һәйәт, ягъни космология һәм аның өлеше булган астрономия Муса әфәнде тарафыннан очраклы гына сурәттә фәнни бер кызык буларак кагылып киткән өлкә булмаган,

---

[1] расадханә – обсерватория.

[2] һөлүл – яңа айның калкуы.

[3] горуб – кояшның баюы.

[4] Уразагыз ураза тоткан көнегездер, уразаны бозуыгыз да уразаны бозган көнегездер (хәдис).

[5] Uralgiray. Mektuplar, s. 4.

әлбәттә. Искә алынган «***Шәригать ничүн роәйәти игътибар итмеш?***» китабы да аннан-моннан йолкып алынган мәгълүматтан гыйбарәт түгел. Бу хезмәтне иксез-чиксез тирә-якны өйрәнә торган табигать фәннәренә мөселман галимнең белеме вә каләме белән язылган бер мөкаддимә, ягъни кереш буларак кабул итү дөрес булыр иде. Кайбер чыганакларга күрә, Муса әфәнде Рус астрономия җәмгыяте әгъзасы булган, ягъни ул астроном буларак җәмгыять йөкләмәләрен рәсми төстә башкаручы тикшеренүче дә. Аның күк җисемнәре хәрәкәтен күзәтү өчен экспедицияләргә барганы мәгълүм. Мәсәлән, Беренче җиһан сугышы барган елларда Муса әфәнде кояш тотылуын күзәтү максаты белән Брест-Литовск шәһәренә бара. Әллә ничә күзлек, озын чәч, тикшеренүләр үткәрү өчен җайланган махсус кием, озын очлы эшләпә киеп, фронт янында үзе белән бер өем астрономик китаплар күтәреп йөргән бу кеше, әлбәттә, хәрбиләрнең игътибарын җәлеп итми калмый. Аны кулга алып, дүрт көн дәвамында сорау алалар һәм, үзеннән куркыныч янамаган берәү булуы аңлашылгач, иреккә җибәрәләр. Муса әфәнденең астрономик җәмгыять әгъзасы булуы һәм бу маҗаралары турыда аның шәкерте Галимҗан Идриси[1] язып калдырган[2]. Муса әфәнде исә үзенең бер мәкаләсендә: «*мөнәҗҗим дәгелем, ләкин һәйәт гыйлеменә, Аллаһның галәмнәренә, табигать хадисәләренә рагъбәтем га-*

[1] Галимҗан Идриси (Ибраһим углы Галимҗан Идриси; 1887–1959) – журналист, дин һәм җәмәгать эшлеклесе. 1914–1915 елларда «Түрк йурду» журналы редакторы. 1915 елдан башлап Алманиядә; 1916–1922 елларда Вюнсдорф хәрби әсирләр лагеренда имам. 1922–1924 елларда Бохара Халык Совет Республикасының Алманиядәге рәсми вәкиле. 1918–1924 елларда Алманиядә «Русия мөселман студентларына ярдәм күрсәтү җәмгыяте»нә нигез салучыларның һәм эшчәнлеген алып баручыларның берсе. 1934–1939 елларда Алмания Тышкы эшләр министрлыгында фәнни хезмәткәр, тәрҗемәче һәм киңәшче; 1939–1945 елларда Пропаганда министрлыгында гарәп һәм төрек редакцияләре мөдире. Сугыштан соң Каһирәдә, Мисыр падишаһы Фарук I-нең сараенда тәрҗемәче була һәм 1945 елда оештырылып, штаб-квартирасы Каһирәдә урнашкан Гарәп Берлегендә (Лига арабских государств) эшли.

[2] İdrisî A. Musa Efendi Bigey. (Ә. Канлыдәрә китабыннан).

*ять бөекдер*», дигән. «*Мөнәҗҗим дәгелем*», ягъни «астроном түгелмен» дигән сүзне ничек аңларга? Махсус астрономик белеме булмаганга күрә үзенә шундый бәя биргәнме? Бу сорауларга җавап кайчан да булса табылыр. Әмма Аллаһ яраткан галәмнәрне, табигать дөньясын өйрәнергә көчле теләккә ия булуы Муса әфәндене тоташ Аллаһ айәтләреннән, ягъни галәмәтләреннән гыйбарәт булган тирә-як мохиткә әһәмият бирмичә, ниһаятьсез галәм вә дөньядан йөзләрен чөереп үзләренең тар күзаллаулары һәм коры хыялларына чумган башка дин галимнәреннән, әлбәттә, бик нык аерып торган һәм әле дә аерып тора.

1909 елда Муса әфәнде дусты Әш-Шинкыйти әфәнденең «***Дәлилүн сарихун фи нөзүли әл-Мәсихи***»[1] («*Мәсихнең иңүе турында ачык дәлил*») исемле хезмәтен бастыра. Бу китапны Әш-Шинкыйти Казанда, җирле мөселманнарның аңа Гайсә пәйгамбәрнең иңүе турында биргән сорауларына җавап рәвешендә язган була. Бастыру эшен Муса әфәнде үз өстенә ала һәм госманлы-татар телендә «*Иман хакында бер ике сүз*» дип исемләнгән кыска гына кереш сүз яза. Муса әфәнденең кайбер дини мәсьәләләргә һәм, гомумән, гыйльми эшчәнлек әдәбенә карашларын ачыклаганга күрә, аны биредә китерүне урынлы күрдек: «*Инсан(ны)ң*[2] *игътикады, иманы – иң мөкаддәс, иң мөхтәрәм сыйфатыдыр. Игътикад инсан(ны)ң һәрбер эшенә, һәрбер хәрәкәтенә әсас*[3] *улур. Игътикад әхлак(ны)ң истикамәтенә*[4]*, игътидаленә*[5] *һәм дә, әксәрийән*[6]*, инхирафына*[7]*, инхыйтатына*[8] *иң бөек сәбәб улу. Инсан(ны)ң «фазыйләт» намында улан иң бөек шәрәфе йалңыз дөрест игътикад(ны)ң сәмәрәсе*[9] *ула билүр.*

[1] Әхмәд бин әл-Әмин әш-Шинкыйти. Дәлилүн сарихун фи нөзүли әл-Мәсихи. Казан: Мәгариф көтебханәсе, 1909. 16 б.

[2] инсан – кеше, адәм баласы; үзенең кем булуын оныткан бере.

[3] әсас – нигез.

[4] истикамәт – дөрес булу; турылык, намуслылык.

[5] игътидаль – чаманы белү; гамәлләрдә урталыкның, чаманың саклануы.

[6] әксәрийән – күбесенчә; күпчелек очракларда.

[7] инхираф – тайпылу, авышу, туры юлдан чыгу.

[8] инхитат – түбәнәю, кимү; кирегә таба китү.

[9] сәмәрә – җимеш; нәтиҗә.

*Ли әҗли зәлик*[1]*, шәригать исламийә дөрест игътикад(н)ы гыйбадәтләр(не)ң, хәйратлар(ны)ң*[2] *һәрберенә әсас итмешдер. Иң бөек гыйбадәт дөрест игътикаддыр, һәрбер гыйбадәт(не)ң иң бөек шарты имандыр.*

*Дәһа*[3] *гамикъ*[4] *мөляхәза*[5] *идәр исәк заһир*[6] *улур: игътикад тарих(ы) инсанийәтдә*[7]*, галәм(е) сәясәтдә гаять мөһим улан рольләр(н)е уйнамышдыр: мөтәгаллибләр*[8] *әлендә*[9] *милләтләр(не)ң биңләрҗә сәнәләр истигъбады*[10]*, залимләр, мөстәбидләр*[11] *әлендә гомум инсанлар(ны)ң мазлумийәте*[12]*, әсарәте*[13]*, раһиб*[14] *йә дәрвиш намында уланлара гобудият*[15] *һәм гыйбадәте агачлар(г)а, ташлар(г)а пәрәстәшләре*[16] *йалңыз хорафи игътикаддан килмешдер. Йагъни мөтәгаллибләр(не)ң, мөстәбидләр(не)ң мәүһүм*[17] *куәтләренә, раһибләр(не)ң, дәрвишләр(не)ң, җәмадләр(не)ң*[18] *йук кодсийәтләренә*[19] *имандан наши*[20] *улмышдыр.*

---

[1] ли әҗли зәлик – бу йөздән, шул сәбәпле, димәк.

[2] хәйрат – изге эшләр, игелекләр; яхшылыклар.

[3] дәһа – тагын; тагын да.

[4] гамикъ – тирән.

[5] мөляхәза – фикер йөртү; тирәнтен уйлау.

[6] заһир – ачык, күренеп торучы; тышкы.

[7] инсанийәт – кешелек дөньясы; цивилизация.

[8] мөтәгаллиб – җиңүгә ирешүче; җиңүче; көчләп буйсындыручы.

[9] әл – кул.

[10] истигъбад – кол итү, колга әйләндерү.

[11] мөстәбид – үзе теләгәнчә эш йөртүче; изүче, деспот.

[12] мәзълумийәт – изелгәнлек; рәнҗетелгәнлек; кимсетелгәнлек; золымга дучар ителгәнлек.

[13] әсарәт – әсирлек; әсир булу.

[14] раһиб – монах.

[15] гобудият – буйсыну; коллык итү.

[16] пәрәстәш – табыну; гыйбадәт кыйлу.

[17] мәүһүм – хыялда гына булган; вәһемгә (күззаллауга, фантазиягә) нигезләнгән.

[18] җәмад – җансыз нәрсә; җанга ия булмаган әйбер.

[19] кодсийәт – изгелек.

[20] наши –…– дән барлыкка килгән.

*Шу кадәр вазыйх[1] шәйләрдә[2] нәуг(ы) инсан хата идәр исә, уйлә хаталар нәуг(ы) бәшәр(н)е[3] әсарәт, рәзаләт[4] бәлияләрендә биңләрҗә сәнәләр хәбес[5] идә билүр[6] исә игътикад(ны) ң галәм(е) иснанийәтдә нәкадәр әһәмияте вар сабит[7] улур.*

*Буның үзәренә[8] бән уйлә[9] мәсьәләләрдә дәһа ике шәй мөляхәза идәрем:*

*Бере: у мәсьәләләрнең галәм(е) исламийәт истикъбаленә[10] тәэсире.*

*Икенчесе: у мәсьәләләрнең бәраһин рийазыйә[11] илә сабит улмыш хакаикъ кәүнийайә[12], һәйәт(е) галәмә[13] нисбәтләре.*

*Әүвәлге ноктадан назар идәр исәк, имам Монтазар[14], хәйат(ы) Хызыр, нөзүл(е)[15] Гайсә кеби мәсьәләләр галәм(е) исламият истикъбаленә гаять фәна[16] сурәтдә тәэсир итмешдер. Гомум галәм(е) исламда истикъбаль ичүн истигъдадсызлык[17] йалңыз уйлә игътикадлардан наши улмышдыр.*

---

[1] вазыйх – анык, ачык; аңлаешлы.

[2] шәй – нәрсә, әйбер.

[3] нәуг(ы) бәшәр – кеше заты.

[4] рәзаләт – хурлык, түбәнлек; бозыклык; яманлык.

[5] хәбес – бикләп тоту; кулга алу; тоткын итү.

[6] идә билүр – итә алыр.

[7] сабит – шиксез, ачык; кузгалмаучы, нык торучы; расланган.

[8] буның үзәренә – моның өстенә.

[9] уйлә – андый.

[10] истикъбаль – киләчәк.

[11] бәраһин рийазыйә – катгый математик дәлилләр.

[12] хакаикъ кәүнийайә – кәвенгә, ягъни барлыкка китерелгән һәрнәрсәгә хас чынбарлыкларга.

[13] һәйәт(е) галәмә – галәм төзелешенә.

[14] Имам Монтазар – Көтелгән имам, Мәһди.

[15] нөзүл – күктән иңү.

[16] фәна – начар, яман; әшәке.

[17] истигъдад – булдыклылык; сәләт; зирәклек, үткенлек; потенциал.

*Икенче ноктадан назар идәр исәк, холүд(е)*[1] *Хызыр, җәсәдейлә*[2] *Гайсә галәйһис-сәламнең иртифагы*[3]*, көнләрнең берендә сәмадан*[4] *нөзүле кеби мәсьәләләр ибтида-и халәкатьдән шу көнә кадәр тәхәллефсез*[5] *сабит ула килмеш хакыйкатьләрә, рийазый борһанлар*[6] *илә катгый сурәтдә сабит улмыш һәйәт(е) галәмә беркадәр мохаләфәт*[7] *идәр.*

*Бән шу ике мөляхәза илә, хакаикъ гыйльмийайә, бәраһин рийазыйә илә сабит улмыш катгыйатә мохаләфәте мөхтәмәл*[8] *улан шәйләри*[9] *шәригать исламия намына нисбәт вирмәкдән иҗтинаб*[10] *идәрем. Уйлә шәйләрә җәсарәт*[11] *идәмәм. Бән бер батыйли*[12] *игътикад идә билүрем. Ләкин у игътикадыми шәригать исламия намына иснад*[13] *идәмәм*[14]*, утанурым*[15]*. Игътикадыми тәэйид итмәк*[16] *сәүдәсейлә шәригать*

---

[1] холүд – мәңгелек.

[2] җәсәдейлә – җәсәде, гәүдәсе белән; гәүдәләтә.

[3] иртифаг – югары күтәрелү; күккә ашырылу.

[4] сәма – күк.

[5] тәхаллеф – соңга калу; артта калу.

[6] борһан – катгый дәлил; кире кагыла алмый торган дәлил; теге яки бу карашның, фикернең дөреслеген катгый сурәттә раслый торган нәрсә.

[7] мохаләфәт – туры килмәү, каршы килү.

[8] мөхтәмәл – булуы мөмкин саналган; булырга мөмкин булган; ихтимал булган.

[9] шәйләри – нәрсәләрне.

[10] иҗтинаб – читләшү, ерак тору.

[11] җәсарәт – кыюлык; батырлык.

[12] батыйль – дөрес түгел, чын түгел; ялган; буш.

[13] иснад – бер эшне яки хәлне бер кешегә кайтарып калдырырга; үз эшен башка берәүгә сылтау.

[14] идәмәм – итә алмыйм.

[15] утанырым – оялам.

[16] тәэйид итмәк – куәтләндерергә, ныгытырга, дөрес итеп күрсәтергә.

*исламийайи ибталь*[1] *идəмəм. Бəн бер кабахəти*[2] *кəндүм*[3] *илтизам*[4] *идəрем. Лəкин у кабахəтемлə шəрыг шəрифи*[5] *тəлвис*[6] *идəмəм.*

*Ли əҗли зəлик, шəригать исламия һəрбер батыйль игътикади «һəува»*[7] *тəсмийə*[8] *идүб, һавайə иттибагдан*[9] *да гаять шиддəтлə*[10] *мəныг*[11] *итмешдер. Катгый борһаны йук шəйлəри игътикаддан тəмамəн нəһьйи*[12] *итмешдер.*

(إِن يَتَّبِعُونَ إِلَّا الظَّنَّ وَمَا تَهْوَى الْأَنفُسُ)[13]

(وَلَا تَتَّبِعِ الْهَوَى فَيُضِلَّكَ عَن سَبِيلِ اللَّهِ)[14]

(إِنْ هِيَ إِلَّا أَسْمَاء سَمَّيْتُمُوهَا أَنتُمْ وَآبَاؤُكُم مَّا أَنزَلَ اللَّهُ بِهَا مِن سُلْطَانٍ)[15]

*Шəрыг шəриф(не)ң бəйанына күрə, батыйль игътикад нəүг(ы) инсанның шəкавəтенə*[16]*, дөньяда һəм ахирəтдə хосранына*[17] *сəбəб улур:*

---

[1] ибталь – юк итү, юкка чыгару; бозыклыгын, ялган булуын күрсəтү.

[2] кабахат – яман нəрсə, алама; начарлык.

[3] кəндүм – үзем.

[4] илтизам – йөклəү; үз өстенə алу, мəҗбүр итү.

[5] шəрыг шəрифи – кадерле шəригатьне.

[6] тəлвис – пычрату; шакшыландыру; начарайту.

[7] һава – хыяллар; уйдырмалар күңел телəге; кəеф; көй (антоним: көйсез; кəефсез).

[8] тəсмийə – исем кушу; исемлəү, атау.

[9] иттибаг – иярү; буйсыну.

[10] шиддəтлə – көч белəн, куəт белəн; каты итеп, нык итеп; нык-лап.

[11] мəныг – тыю; туктату, булдырмау.

[12] нəһъйи – тыю.

[13] «алар бары тик үзлəренең уйдырмаларына һəм нəфеслəренең һаваланауларына иярəлəр» (Коръəн, 53:23).

[14] «һаваланауга иярмə, юкса сине Аллаһ юлыннан адаштырыр» (Коръəн, 38:26).

[15] «чынлыкта болар, сез үзегез һəм сезнең аталарыгыз кушкан исемнəрдəн кала, берни түгел. Аллаһ алар белəн һичнинди хакимлек иңдермəде» (Коръəн, 53:23).

[16] шəкавəт – бəхетсезлек; бəдбəхетлек.

[17] хосран – үкенү, үкенеч, хəсрəтлəнү.

(قُلْ هَلْ نُنَبِّئُكُمْ بِالْأَخْسَرِينَ أَعْمَالًا الَّذِينَ ضَلَّ سَعْيُهُمْ فِي الْحَيَاةِ الدُّنْيَا وَهُمْ يَحْسَبُونَ أَنَّهُمْ يُحْسِنُونَ صُنْعًا)[1] *18:103–104*

*Ислам кеби иң пакь, иң мөкаддәс бер дин сәмави, әлбәттә, игътикад шәэнендә[2] соң дәрәҗә игътина[3] идәр һәм итмешдер. Йалңыз катгый борһан үзәренә тәэсис[4] кыйлынмыш игътикади кабул идүб, борһанлә мөәййәд[5] дәгел игътикади һичбер адәмә илзам[6] итмәмешдер.*

*Бән шәрыг шәрифнең шу әсас кавименә[7] игътикад, һәм дә у бөек мөсагадәсейлә[8] интифаг[9] идүб, игътикадда хөррияти иң мөкаддәс бер хак игътибар идәрем. Мәшһүр, ләкин асылы йук игътикадлари тәнкыйд һәм җәрах[10] итмәкдән истинкяф[11] идәмәм. Хәйат(ы) Хызыр, нөзүл(е) Гайсә кеби мәсьәләләрдә хөрриятлә сөйләмеш исәм, шу әсаса[12] мөбни[13] иде.*

*Нөзүл мәсьәләсендә битарафлыгыми, тәгассубым[14] йуклыгыны күстәрмәк ичүн, әл-остаз Әхмәд әфәнде әш-Шинкыйтый хәзрәтләренең каләмейлә[15] тәэлиф кыйлынмыш[16] шу*

[1] «Әйт: «Үзләрен игелек кыйлучыларбыз, дип саный торып та, түбән яшәештәге (дөньядагы) тырышлыклары юкка чыгып кыйлмышлары белән иң үкенечлеләр турында хәбәр җиткерикме сезгә?»» (Коръән, 18:103–104).

[2] шәэн – эш, мәсьәлә.

[3] игътина – әһәмият бирү; игътибар итү.

[4] тәэсис – төзү, оештыру; нигез салу.

[5] мөәййәд – ныгытылган, куәтләнгән.

[6] илзам – тиешле итү; йөкләү.

[7] кавим – туры; чын, дөрес, хакыйкый.

[8] мөсагадә – мөмкинлек бирү, ярдәм итү; үзара ярдәмләшү.

[9] интифаг – файдалану; файда күрү.

[10] җәрах – яралау, җәрәхәтләү; мыскыллау.

[11] инстинкяф – кабул итмәү, кире кагу; баш тарту.

[12] шу әсасә – бу әсаскә, бу нигезгә.

[13] мөбни – төзелгән, корылган.

[14] тәгассуб – нәрсәне дә булса күрә алмау; нәрсәгә булса да нәфрәт белән карау; фанатизм.

[15] каләмейлә – каләме белән.

[16] тәэлиф кыйлынмыш – төзелгән, язылган.

*рисаләйи*[1] *нәшер итмәги мөнасиб*[2] *күрдек. Мәсьәлә ләһендә*[3] *йә галәйһендә*[4] *сүз сөйләйән инсан, һәрхәлдә, дәлилейлә сүз сөйләсүн. Буйлә мәсьәләләрдә мохалифи*[5] *һичбер вакыт тәзълил*[6] *итмәсүн.*

*Инсаф*[7] *шудыр. Әдәб шудыр*»[8].

Шулай ук Муса әфәнденең 1909 елда дөнья күргән «***Китабу әл-мөвафәкати***»[9] («Үзара килештерү китабы»), «***«Мөвафәкать» мөкаддимәсе***»[10] («»Мөвафәкать»кә кереш сүз»), «***Ифадату әл-кирами***»[11] («Хөрмәтлеләрнең әйткәннәре») кебек хезмәтләрен искә алып узарга кирәк.

«***Китабу әл-мөвафәкати***»нең асыл нөсхәсе миладите 790 елда вафат булган имам Әбү Исхак Ибраһим ибне Муса әш-Шатыйби каләме белән язылып, төрле фикъһы мәзһәбләренең хөкемнәрен үзара килештерү мәсьәләләренә багышлана. Гарәп телендә язылган бу хезмәтне Муса әфәнде басмага әзерли, госманлы-татар телендә шактый күләмле һәм гарәп телендә кыска гына кереш сүз язып бастыра. «Шура» журналы бу китап турында анонс бирә: «*Һиҗри 509 вафат булган Әбу Исхак Ибраһим бин-е Муса әш-Шатыйбиның Әбу Хәнифә белән Малик мәзһәбе арасында булган үзара ярашкан*

---

[1] рисаләйи – рисаләне, ягъни язманы, мәкаләне.

[2] мөнасиб – ятышлы; яраклы; килешеп торучы.

[3] ләһендә – аның файдасына.

[4] галәйһендә – аңа каршы.

[5] мохалифи – каршы килүчене; капма-каршы фикердә торучыны.

[6] тәзълил – адашуда гаепләү, туры юлдан тайпылуда гаепләү.

[7] инсаф – гадел; аек акыллы.

[8] Муса Бигиев. Иман хакында бер ике сүз. Әхмәд бин әл-Әмин әш-Шинкыйти. Дәлилүн сарихун фи нөзүли әл-Мәсихи. Казан: Мәгариф көтебханәсе, 1909. Б. 2–4.

[9] Китабу әл-мөвафәкати ли-имами әл-хафизи әл-мөфассири әл-фәкыйһи әл-усулийи әш-шәйхи Аби Исхак Ибраһим ибни Муса әш-Шатыби радыйа Аллаһу ганһу. Казан: Сабах көтепханәсе, 1909. 190 б.

[10] Муса Җаруллаһ. Әл-Мөвафәкать мөкаддимәсе. Казан, 1909. 14 б.

[11] Ифадату әл-кирами. Казан: Харитонов матбагасы, 1909. 80 б.

*һәм ярашмаган урыннан хакында язылган ошбу бөек әсәрне фазыйль[1] Муса Җаруллаһ әфәнде тәсъхыйхы[2] белән «Сабах» тарафыннан нәшер ителә башлавы исемебезгә килгән беренче формасыннан мәгълүм булды. Бу кебек газиз һәм файдалы бер әсәрне нәшер итүе өчен гыйлем әһелләре «Сабах»ка рәхмәтле булсалар кирәк. Баш тарафына мөхтәрәм Муса әфәнде тарафыннан төркичә язылмыш мөкаддимәсе «Әл-Мөвафәкать» өчен генә дәгел, бәлки гомуми сурәттә усулел-фикъһы хакында мөкаддимә вә тәхсыйл-е гыйлем өстендә булган шәкертләр өчен бер раһбәр хисап ителсә урынлыдыр. Муса әфәнденең китап тәсъхыйх итмәктә булган тырышлыгы шул дәрәҗәдер ки, әгәр дә ошбу хәлендә дәвам итсә, ислам әсәрләрене тәсъхыйх итеп нәшер итмәктә булган мөстәшрикъларның шөкерләреннән ислам галәменең котылуына сәбәб булачагы өмет кыйлыныр»*[3].

Бу анонстан аңлашылганча, «Шура»ны җитәкләгән Ризаэтдин хәзрәт Муса әфәнде эшләгән эшнең әһәмиятен бик яхшы аңлаган һәм аның бик кирәкле булуын халыка да җиткерергә тырышкан. Әлеге белдерүдән әсәрнең әлегә кадәр үзенең әһәмиятен югалтмаган булуы күренеп торганга күрә, аның хәзерге заман мәдрәсә һәм югары ислам уку йортларында кулланылачагына өмет бар.

Хәдис гыйлеменә багышланган «***Ифадату әл-кирами***» исемле китапны Муса әфәнде мәдрәсәләрдә дәреслек булارак кулланылуын өмет итеп бастырган. Асылда хезмәт миլади 1448 елда вафат булган күренекле дин галиме, фәкыйһ, хәдис белгече Шиһабетдин Әбу әл-Фазыл Әхмәд ибне Гали әл-Гаскалянинең «*Булугу әл-мирами мин шәрхи әдиллати әл-әхкями*» исемле әсәренә шәрех (аңлатма) рәвешендә язылган. Аның басыла башлавы турында анонс «Шура» журналы сәхифәләрендә чыга: «*«Булугу әл-мирами мин шәрхи әдиллати әл-әхкями» исемендә улан хәдис китабына фазыйл мөхтәрәм*

[1] фазыйль – яхшы холыклы; инсафлы, намуслы; галим кешегә карата кулланыла торган хөрмәтләү сүзе.

[2] тәсъхыйх – дөресләү; төзәтмәләр кертү.

[3] Әл-Мөвафәкать // Шура. № 10, 1909. Б.315.

*Муса әфәнде тарафындан йазылмакда улан бөек шәрех китабы Казан шәһәрендә Харитонов матбагасында басылырга башландыгы исемемезгә килмеш бер формасындан мәгълүм улды.*

*Муса әфәнденең гарәбчә йазмакда улан мәһарәте гарәб әдибләренең икърарлары илә вә голүм исламиядә улан кәмаләте үзенең остазларының шәһадәте илә мәгълүм улдыгындан башка Петербург дарел-фөнүнендә хокук дәресләренә мөдавәмәт итмәклә ислам фикъһысыны, Гареб хокукы илә мөкайәсә әйләргә моваффак улмышдыр. Ошбу сәбәбдән Муса әфәнденең бу әсәре газиз бер гыйлем хәзинәсе улса кирәк. Бәзем өмидемез шуйләдер.*

*Китабның наширләре «Вакыт» илә «Шура» наширләре илә берлекдә «Шәрык» көтебханәсе идеки тышында йазылмышдыр»*[1].

Алга таба Муса әфәнде бу хезмәтнең басылуын кичектереп торуы турында белдерә. Бу җәһәттән, әлеге әсәрне басылмаган хезмәтләр рәтенә кертү дөрес булыр.

Ниһаять ««***Мөвафәкать» мөкаддимәсе***» исемле бер хезмәткә килеп җиттек. Монысы – бая искә алынган «***Китабу әл-мөвафәкати***» исемле хезмәткә карата язылган кереш сүз. Аны Муса әфәнде «***Китабу әл-мөвафәкати***»нең үзендә дә урнаштырган (б. 2–15), һәм ««***Әл-Мувафәкать» мөкаддимәсе***» исеме белән аерым китап итеп тә бастырып чыгарган. Аның татар теленә тулы тәрҗемәсе китабыбызның кушымтасында бирелде[2].

## Фикъһыга караган хезмәте

1910 елда Муса әфәнде үзенең иң күләмле хезмәтләреннән берсе булган «***Кавагыйд фикъһийә***»[3] («Фикъһы кагыйдәлә-

---

[1] Тәкъриз // Шура. 1909. № 3. Б. 88.

[2] Карагыз: III Бүлек. 2: «әл-Мөвафәкать»нең нәшер ителүенә кагылышлы бер-ике сүз.

[3] Муса Җаруллаһ Бигиев. Шәригать исламия әлифбасы мөсабәсендә игътибар кыйлына билүр Кавагыйд фикъһийә (әхкям шәргыйә мәҗәлләсенә мәдхәл улмак сыйфатыйлә) остаз мөхтәрәм Ри-

ре») исемле китабын бастырып чыгаруга ирешә. Әлеге әсәр ифрат та әһәмиятле һәм үзенчәлекле булганга күрә, аның турында берникадәр күбрәк мәгълүмат бирүне урынлы дип таптык.

Башлап шуны әйтергә кирәк: гыйльми эшчәнлегендә Муса әфәнде иң күп көчен ислам фикъһысы, ягъни хокук теориясе һәм практикасына багышлаган. Ул фикъһының җәмгыятьнең үсешенә, куәтенә, гаделлегенә ясый алган бәрәкәтле, әмма ачылмый калган егәре вә мөмкинлекләренә юл ачарга тырышкан, аны борынгыдан килеп, инде күптән катып калган калыплардан, тормышның агышына киртә булган алымнарыннан аруларга алынган, фикъһыны гади халыкка да аңлаешлы итеп тормышка якынайту турында хыялланган һәм шул юнәлешләрдә армый-талмый эшләгән. Бу хезмәттә Муса әфәндегә, фикъһыны яхшы белү белән бергә, Көнбатыш хокук системалары белән таныш булуы да, Петербург университетының Юридик факультетында өч ел дәвамында укуы да, урыс телен камил дәрәҗәдә белүе дә, әлбәттә, ярдәм итә. 1939 елда Русияне ташлап киткәнгә кадәр, Бигиев мөселман хокукы буенча берничә махсус хезмәт бастыра. Дини гыйлемнең бу өлкәсенә караган китаплар язуны ул горбәтлектә дә дәвам итә. Гомумән, аның һәр әсәрендә диярлек фикъһы мәсьәләләре кузгатыла, карала, тикшерелә.

Муса Бигиевнең фикъһы бинасын торгызу өлкәсендәге гамәли эшчәнлегенең күркәм бер мисалы булып, аның шәригать проблемаларына багышланган журнал булдыру гамәлләре тора. Дөресен әйткәндә, мөселманнар өчен шәригать хөкемнәре буенча басма орган булдыру максаты, сәер булып тоелса да, көн үзәгенә Россия хөкүмәте тарафыннан куела. Мәсәлән, 1902 елда Русия императоры инициативасы белән

за әфәнде хәзрәтләренең иршады, нәзарәте һәм заманы тәхтендә Муса Җарулла Бигиев каләмейлә тәэлиф кыйлынмышдыр. Казань: Электро-Типография «Урнэк», 1328 [1910]. 232 б. Китапның исемендә кулланылган заман сүзе безгә мәгълүм булган «заман», «вакыт» (زمان) мәгънәсенә ия булган сүз түгел, ул ясалышы буенча тәмам башка сүз булып, заман (ضمان) – «җаваплылык», «гарантия» мәгънәсенә ия.

бу мәсьәлә, аерым алганда шәригатьнең кайбер өлкәләрендә тәртип урнаштыру мәсьәләсе, яңа төзелгән сенатор граф Пален җитәкчелегендәге махсус комиссиягә йөкләнә. 1908 елның июнендә әлеге комиссия ревизия белән Төркестанга барып төшә. Ревизиядән тыш, комиссия Төркестан казыйлары өчен шәригать хөкемнәре буенча журналга нигез салырга тиеш була. Әмма граф Пален Төрекмәнстанда шәригатьне тиешле дәрәҗәдә белүче бер генә кешене дә тапмаган, имеш. Мөгаен, җирле фәкыйһләр бу эшкә алынырга теләмәгәннәрдер. Ни генә булса да, Төркестан мөселманнары үзләре башкарып чыгарасы бу эш урынына комиссия карамагында Көнбатышта һәм Русиядә шәрык белгечләре тарафыннан шәригатькә кагылышлы язылган мәкаләләр һәм китаплардан йолкып-йолкып тупланган бер проект әзерләнә. Асылда әлеге проектның нигезенә инглиз шәркыятьчесе Вильсонның Һиндестан мөселманнары өчен язылган хезмәте салына. Аңа «*Опыт систематического изложения главнейших начал шариата, применяемых ныне в коренных областях Туркестанского края*» дигән исем бирелә.

Әлеге эшләрне күзәтеп торган татар матбугаты искә алынган проектның 1909 елда Ташкентта мөселман голәмәсе һәм рус белгечләре җыелышы хозурында рус һәм үзбәк телләрендә укылып тәкъдим ителүе турында язган. Ул җыелышта катнашкан мөселман голәмәсе үзен бик сүлпән күрсәтә һәм уку дәвамында бер генә төзәтмә дә кертми, бары тик документны борынгы мөселман чыганаклары белән чагыштырып чыгарга рөхсәт сорап, үз фикерләрен соңрак белдерәчәгенә ышандыра. Җыентык ляихәсенә кайбер өстәмәләр һәм төзәтмәләр кертелгәннән соң, ул «*Мөнтәхәб әл-мәсаъил*» дигән исем белән рус һәм үзбәк телләрендә дөнья күрә. Җыентыкта гаилә хөкемнәре, мирас һәм милек хөкемнәре кебек ике фасыл һәм җинаятьләрне хөкем итүгә кагылышлы бер мөстәкыйль маддә була.

Югарыда язылганнардан аңлашылганча, Төркестан мөселманнарының хокукый грамоталылыгын ригая кылган Русия хакимияте Идел-Урал төбәгендә, Себердә һәм башка җир-

ләрдә яшәгән татарлар турында кайгыртуны кирәксенмәгән булса кирәк. Шулай да, Муса Бигиев туган ягына әйләнеп кайтканчы ук, Русия мөселманнары арасында шәригать хөкемнәре турында журнал булдыру идеясе барлыкка килә. Әлеге идея мөселман җәмгыятендә һәм ислам дөньясында барган тирән үзгәрешләр шаукымы белән шәригать проблемаларының үзләрен кискен сурәттә сиздерә башлавының нәтиҗәсе була. Шуңа күрә ул заманда Русия мөселманнарының шәригать кануннары һәм дини хокук өлкәсендә активлык күрсәтә башлавы табигый күренеш булып тора. Мәсәлән, 1905 елдан башлап күренекле җәмәгать эшлеклесе Әхмәд-Һади Максуди шәригать хөкемнәренә багышланган «Һилал» (Ярымай) исемле җыентык нәшер итеп килгән була. Шул ук 1905 елда Оренбург Диния нәзарәтендә ислам хокукы мәсьәләләре буенча махсус журнал булдыру турында сүз кузгатыла. Әлеге ике күренеш Русиядә башланган инкыйлаб һәм шуның белән бергә иҗтимагый тормышта хөррият идеяләренең баш күтәрүе белән бер вакытта мәйданга чыга. Бу исә мөселман зыялыларын беренче нәүбәттә нәкъ менә шәригать мәсьәләләре кызыксындыруын дәлилли. Шул елдан башлап Русия мөселман матбугатында ислам хокукы буенча махсус басма булдыру проблемасы даими төстә чагылыш таба. Аерым алганда, «Тәрҗеман» гәзите, Русия мөселманнары өчен, Төркиядә 1822–1895 елларда чыккан «Мәҗәллә-и әхкям-и гадлия» («Гадел хөкемнәр журналы») исемле шәригать журналын тәкъдим итә. «Идел», «Йолдыз» һәм башка татар вакытлы басмалары да үз битләрендә бу мәсьәлә хакында фикерләшүгә урын бирәләр. «Шура» журналы һәр санында әлеге темага багышланган аерым рубрика алып бара. Татар басмаларында никадәр генә каршылыклы фикерләр яңгыраса да, асылда мөселманнарның мондый журналга ифрат дәрәҗәдә зур ихтыяҗ кичерүләре бертавыштан танылa. Шуңа күрә татар мөселман лидерларының Төркестан мөселманнары өчен шәригать җыентыгы оештыру тәҗрибәсе белән кызыксынулары табигый бер хәл була.

Муса Бигиев бу җитди мәсьәләне хәл итүдә Русиягә кайткан көненнән башлап актив һәм эзлекле төстә катнаша башлый. Мәсәлән, югарыда искә алынган «Мөнтәхәб әл-мәсаъил» җыентыгы дөнья күргәннән соң, ул граф Паленның комиссиясенә хат язып, бу басманың Эчке Русия мөселманнарына кайчан барып җитәчәге турында сорау куя; 1909 елдан башлап татар гәзитләрендә шәригать журналы булдыруның кирәклеге һәм актуальлеге турында мәкаләләр бастыра. Хөкүмәт чиновниклары тарафыннан Төркестан мөселманнарына тоттырылган «*Мөнтәхәб әл-мәсаъил*»не Муса әфәнде бик уңышсыз, начар һәм мөселманнарның дини хисләрен мыскыл итүче бер китап буларак бәяләп чыга һәм әлеге җыентыкта булган барлык маддәләрне кискен тәнкыйтькә тотачагы турында белдерү ясый.

Боларны истә тотканда, «Шура» журналы мөхәррире Риза хәзрәт Фәхретдиннең шәригать буенча мәҗмуга әзерләү һәм чыгару эшен ни өчен нәкъ менә Муса Бигиевкә тәкъдим итүе аңлашыла. Муса әфәнде бу тәкъдимне кабул итә һәм журнал белән бәйле эшне башлап җибәрү йөзеннән «*Кавагыйд фикъһийә*»не әзерләп чыгара. Китапның кереш сүзендә ул болай дип язган: «*Моннан берничә ел элек ислам хокукын хәзерге гасырның гыйльми теле белән бәян итү шәрәфен*[1] *казану шәвыкы*[2] *мине кайбер тәшәббесләргә*[3] *этәргән иде. Ул шәвыкъның хәрәкәтләндерүе белән мин «Ифадәт әл-кирам»*[4] *исемле китапны нәшер итәргә керешеп, «Кыйсем әл-гыйбадат»*[5]*тән дүрт-биш кадәр кирәкле нәрсәләрне бастырган идем. Нәтиҗәдә, ислам шәригате кебек могъҗизави бер шәригатьнең носус китабия*[6] *һәм носус нәбәвияләрен*[7]

[1] шәрәф – хөрмәт; намус; кадер, дәрәҗә.

[2] шәвыкъ – көчле теләк; нык омтылыш.

[3] тәшәббес –ниндә булса бер эшкә тотыну; башлам; башлау; инициатива.

[4] Ифадәт әл-кирам. Казань: Типография Харитонова, 1909. 80 б.

[5] Кыйсем әл-гыйбадат – Гыйбадәтләр өлеше.

[6] носус китабия – язылган / язма чыганаклар; Китаптагы (ягъни Коръәндәге).

[7] носус нәбәвия – пәйгамбәргә караган чыганаклар, ягъни Мөхәммәт пәйгамбәрнең сөннәтендәге.

*күңелем канәгать булырлык дәрәҗәдә аңлату һәм тәфсир кыйлу вазифаларында булдыксызлыгымны тоеп, (عَسَى أَن يَهْدِيَنِ رَبِّي لِأَقْرَبَ مِنْ هَذَا رَشَدًا)[1], дигән өмет белән «Ифадәт әл-кирам»ны нәшер итүне вакытлыча читкә куйдым. Соңрак илаһи рәхмәт буларак, быел мөхтәрәм остаз Риза әфәнде[2] хәзрәтләренең гыйльми мәҗлесләреннән файдалана алу бәхетенә лаек булдым. Остаз хәзрәтләре шәрыгъ шәрифнең[3] таралышын киңәйтүдә «Әхкям шәргыя мәҗәлләсе»[4]нең Русия мөселманнары өчен бигрәк тә кирәкле һәм әһәмиятле чыганак булуы турында иң тәэсирле сүзләрен миңа һәрвакыт сеңдерә тордылар, олы бер хезмәтне үз өстемә алырга дәгъвәт иткән[5] кебек миңа атап хитаб итәрләр[6] иде. Остаз хәзрәтләренең юнәлеш бирү бәрәкәте белән миндә рагъбәт[7] уянды. «Мәҗәллә-и әхкям-и шәргыя»[8]не бергәләп язачак булдык. Йә бер үрнәк, йә бер мөкаддимә булыр дигән өмет белән мин шәригать кагыйдәләрен мөмкин булган кадәр тулы сурәттә нәшер итүне урынлы күрдем дә, остаз хәзрәтләренең нәзарате астында шәригать кагыйдәләрен мөмкин кадәр тулы бер шәкелдә җыйдым. Әлеге кагыйдәләрне йә ачыклау вә аңлату, йә исбат итү өчен һәр кагыйдәдән соң берничә юл өстәп яздым. Кагыйдәләрне җыйганда аларны билгеле бер тәртипкә салып баруны кайгырту мөмкин түгел иде. Бастырганда да тәртипкә китерү мөмкин булмады. Ләкин ул*

[1] «Бәлки Раббым мине моннан якынрак булганына юнәлтер» (Коръән, 18:24).

[2] Риза әфәнде – Ризаэтдин Фәхретдинов.

[3] шәрыгъ шәриф – кадерле, изге шәригать.

[4] «Әхкям шәргыя мәҗәлләсе» («Шәригать хөкемнәре журналы») – Риза Фәхретдиннең Русия мөселманнары өчен чыгарырга ниятләгән журнал исеме.

[5] дәгъвәт итәргә – чакырырга.

[6] хитаб итәргә – эндәшергә; сүзне берәүгә атап әйтергә.

[7] рагъбәт – нык, көчле теләк; омтылыш.

[8] «Мәҗәллә-и әхкям шәргыя» («Шәригать хөкемнәре журналы») – булачак шәригать журналына Риза Фәхретдин белән Муса әфәнде тарафыннан бирелгән исем.

*җитешсезлек китапның маддәләренә[1] бәйле кимчелек түгел иде; шуңа күрә, зарури хаҗәтне тормышка ашыруда соңга калмау йөзеннән кабул ителде.*

*Бу китапны җыйганда кимчелекләрдән арыну максаты белән өстемә ике вазифа йөкләдем: бере – иң ышанычлы чыганакларны игътибардан читтә калдырмау, икенчесе – соңгы вакытларда язылган китапларның тәэсире астында калмау. Шуңа күрә бу китап «иң ышанычлы һәм саф ислам хокукы» сыйфатында кабул кыйлына алырлык дәрәҗәгә килде.*

*Мин бу китапны таләбәләргә[2], Русия голәмәсенә бу сыйфатта бу юлы гарыз кыйлып[3]; хөрмәтле әфәнде затлар аны укып чыкканнан соң тәнбиһләрен[4] үтенәм. Чөнки якында, иншаллаһ, нәшер кыйлыначак «Әхкям шәргыя мәҗәлләсе» ошбу «Кавагыйд фикъһия» өстенә нигезләнәчәк»[5].*

Әлеге кереш сүздән аңлашылганча, «*Кавагыйд фикъһийә*»-не Муса әфәнде Русия татар-мөселман җәмәгатьчелегенә «*иң ышанычлы һәм саф ислам хокукы*» буларак тәкъдим иткән. Чыннан да, бу китап дөнья күргәнче, Русия мөселманнарының кулында шәригать кагыйдәләрен системалы, эзлекле аңлатып биргән хезмәт булмаган. Муса әфәнденең әлеге әсәре үз вакыты өчен дә, хәзерге көндә дә Русия имамнарына, муллаларына, мөгаллим вә шәкертләренә һәм, гомумән, мөселман җәмәгатьчелегенә шәригать хөкемнәренең нигезләрен, шәригать хөкемнәренең асылында нинди принциплар ятканлыгын аңлатучы бердәнбер хезмәт булып тора.

«*Кавагыйд фикъһийә*», чыннан да, әлеге гыйлем турында аңлаешлы төстә мәгълүмат биреп, аны гади халыкка якынайта. Мисал өчен, китапның мөкаддимәсеннән бер өзек

[1] маддә – нинди дә булса документның эчтәлеген тәшкил итә торган бүлекчә, статья.

[2] таләбә – шәкерт; студент.

[3] гарыз кыйлып – тәкъдим итеп.

[4] тәнбиһ – кисәтү; тәнкыйть; киңәш.

[5] Парча хәзерге татар теленә яраклаштырылды.

китерик: «***Фикъһы[1] гыйлеме: һәйәт иҗтимагыя[2] әгъзасы буларак, кешенең үз хокукларын һәм үз вазифаларын тулысынча белүе***.

*Фикъһы китапларында имам Әбү Хәнифә, разыя Аллаһу ганһу[3], хәзрәтләреннән тапшырылып, фикъһы гыйлеменең ни булуы һәрнәрсәне үзенә сыйдырган* (معرفة الناس ما لها و ما عليها)[4] *дигән билгеләмә дә белдерелгән. Ул тәгърифкә[5] күрә, «фикъһы гыйлеме»нең даирәсе гаять киңдер: игътикад[6], әхлак, гыйбадәтләр өлешләре дә; мөнакәхат[7], мөгамәлят[8], гокубат[9] тармаклары да фикъһы гыйлеменең эчтәлеген тәшкил итә. Сәләф[10] биргән билгеләмәдә шулай иде. Соңрак килгән әһле тәдвин[11], шәригатькә караган гыйлемнәрне тасниф[12] икәндә, ягъни сыйныфларга бүлгәндә, тәүхид гыйлемен*

---

[1] фикъһы (гарәп.: тирәнтен аңлау, тирәнтен белү; асылын күрү) – мөселман кешенең гыйбадәттә, башкалар белән мөгамәләдә һәм үзенә карата үз-үзен тотышы кагыйдәләрен (шәригать хөкемнәрен) барлау һәм булдыру белән шөгыльләнә торган дини гыйлем.

[2] һәйәт иҗтимагыя – җәмгыять төзелеше; иҗтимагый система.

[3] тәрҗемәсе: Аллаһ аңардан разый булды яки Аллаһ аңардан разый булсын.

[4] тәрҗемәсе: Кешеләрнең үз хакларын һәм аларданниләр таләп ителгәнне белүләре.

[5] тәгъриф – билгеләмә; таныту, белдерү, аңлату; билгеләү.

[6] игътикад – ышану, инану; диндә кешенең ышанырга тиешле булган нәрсәләре.

[7] мөнакәхат – никахлашулар; гаилә кору турындагы килешүләр.

[8] мөгамәлят – мөгамәләләр; фикъһыдагы кешеләр арасындагы мөнәсәбәтләрнең, үзара аралашуның хокукый яссылыклары.

[9] гокубат – фикъһының җинаятьләр өчен җәза бирүгә кагылышлы өлеше.

[10] сәләф – турылыклы мөселманнар буларак танылган борынгылар: пәйгамбәрнең сәхабәләре, алардан гыйлем алган мөселманнар буыны (табигыйннар) һәм табигыйннардан белем алган өченче буын вәкилләре.

[11] әһле тәдвин – нәрсәне дә булса тәртипкә китерүчеләр; системалаштыручылар.

[12] тасниф – бүлекләргә, тармакларга аеру; кулланылышны җайга салу өчен сыйныфлаштыру, төрләргә бүлү.

*үз чикләренә, әхлак гыйлемен үз чикләренә ия булган аерым мөстәкыйль гыйлемнәр итеп күреп; фикъһы гыйлемен гыйбадәтләр, мөнакәхат, мөгамәлят, гокубат тармакларына аерганнар.*

*Тасниф, тәдвин мәсьәләсе бер истыйляхтыр*[1]*. Истыйляхка караган нәрсәләрдә, мәгълүмдер, тарлык булмас. Игелекле сәләф, Коръән айәтләреннән, пәйгамбәр сөннәтеннән үзләштерелгән һәммә гыйлемнәрне бер урынга туплап, аны «Гыйлем-е фикъһы», дип атаганнар. Соңрак килгән әһле гыйлем игътикадны, әхлакны аерып алып, гыйлем-е фикъһыны гыйбадәтләр, мөнакәхат, мөгамәлят, гокубат өлешләреннән гыйбарәт иткәннәр. Биредә нинди дә булса мәгънәви каршылык юк.*

*Әһле гыйлемнең игътикадны, әхлакны аерып алганнары кебек, без дә гыйбадәтне, аның махсус әһәмияткә ия булуына күрә, аерып алсак, гыйлем-е фикъһы мөнакяхат, мөгамәлят, гокубат кыйсемнәреннән гыйбарәт булыр.*

*Гыйлем-е фикъһыга биргән билгеләмәбездә без бу юлны сайлап: «Гыйлем-е фикъһы: һәйәт иҗтимагыя әгъзасы буларак кешенең үз хокукларын һәм үз вазифаларын тулысынча белүдер», – дидек.*

*Һәйәт иҗтимагыя ул йә гаилә, йә мәдинә*[2]*, йә дәүләтдер.*

*Кешене үз башына яши торган бер хайван, дип фараз итсәк, ул чакта кешегә һичбер хак, һичбер вазифа хас булмас иде. Шуңа күрә билгеләмәбездә «һәйәт иҗтимагыя әгъзасы буларак» дигән үзенчәлекне искә алдык.*

*Безнең билгеләмәбезгә күрә, гыйлем-е фикъһы (хәзерге гасырның теле белән әйтсәк, гыйлем-е хокук) өч тармактан гыйбарәт булыр: 1) гаиләдә әгъза буларак кешенең хокукларына һәм вазифаларына бәйле булган мәсьәләләр – ягъни мөнәкяхат тармагы була; 2) мәдинәдә йә дәүләттә әгъза буларак кешенең хокукларына һәм вазифаларына кагылыш-*

---

[1] истыйлях – теге яки бу өлкәдә кулланыла торган махсус атама, термин.

[2] мәдинә – кала, шәһәр; биредә бер җирлектә (торак пунктта) яшәүчеләрдән гыйбарәт булган җәмәгатьчелек.

*лы мәсьәләләр, йә кануннар – ягъни мөгамәлят тармагы була; 3) мөнәкяхат һәм дә мөгамәлят кануннарын үтәү һәм дә зарардан саклану өчен гамәлгә куелган кануннар – гокубат тармагы була.*

*Мөнәкяхат тармагы никах, талак, бала имезү, нәфәка[1], фараъиз[2] кебек китапларда; мөгамәлят тармагы бәйгъ[3], иҗарә[4], кәфалә[5], хәвалә[6], әманәт, һиббә[7], ширкәт кебек күпсанлы китапларга, китапларда күпсанлы фасылларга галә хәсби әл-исътыйлях[8] бүленеп, җөзьиятьнең[9] хосусый хөкемнәре тәфсилле сурәттә бәян кыйлына.*

*Көтеб фикъһиядә шул рәвешле тәфсилләп бәян кыйлынган җөзьи[10] мәсьәләләргә «фөруг фикъһия»[11], диелә.*

*Айәтләрнең, хәдисләрнең [мәгънәләре турында фикер йөрткәннән соң] шулардан фөруг фикъһияне чыгарган фөкаһа-и кирам[12] Коръән кәрим белән Сөнән нәбәвиядән[13] – фөруг фикъһиягә нисбәтән әһәмияте тагын да олырак булган усул көллияне [гомуми асылларны] – кавагыйд фикъһияне чыгарганнар».*

---

[1] нәфәка – гаилә әгъзаларына тотылырга тиешле, аларның хакы булган матди (шул исәптән – акчалата) чыгымнар.

[2] фараъиз – варислар арасында мирас бүлү кагыйдәләре.

[3] бәйгъ – алыш-биреш, сәүдә.

[4] иҗарә – хакын түләп нәрсәне дә булса вакытлы сурәттә файдаланып тору; аренда.

[5] кәфалә – ышандырып үз өстенә алучылык; гарантия бирү.

[6] хәвалә – почта аша, яки башка арадашчы аркылы акча күчерү.

[7] һибә – бүләк итеп бирү.

[8] галә хәсби әл-исътыйлях – истыйлях тәртибендә.

[9] җөзьиять – нәрсәнең дә булса кечкенә өлешләре; вак, әһәмиятсез нәрсәләр.

[10] җөзьи – гомумнең кечкенә өлеше булган; вак, кечкенә; әһәмиятсез.

[11] фөруг фикъһия – фикъһының (хокук гыйлеменең) тармаклары.

[12] фөкаһа-и кирам – хөрмәтле фәкыйһләр.

[13] сөнән нәбәвия – Мөхәммәт пәйгамбәрнең (ﷺ) сөннәтләре, ягъни хәдисләре аша җиткерелгән кагыйдәләр, әдәпле вә әхлаклы мөгамәлә үрнәкләре.

Менә шундый файдалы, тирән һәм гамәлдә куллану өчен тиңдәше булмаган «*Кавагыйд фикъһийә*»не Төркия халкына ирештермәс өчен, шәйхелислам хәзрәтләренең фәрман чыгаруы сәер эш булып күренә. Әлеге фәрманның нигезендә ниләр ятканын без Муса әфәндедең 1913 елда «Ил» гәзитендә бастырган бер мәкаләсеннән укып белә алабыз. Галимнең язганнары госманлы шәйхелисламнарына карата кискен тәнкыйть булып яңгырый, шуңа күрә укучыны ул фикерләр белән таныштырып узу дөрес булыр. Муса әфәнде «*Тәъәссеф итмештем, артык аңладым*» («Кайгыга төшкән идем, инде аңладым») исемле мәкаләсендә болай дип язган: «*Шунысы кызыклы ки, иң ышанычлы чыганаклардан алынган иң мәгъкуль [шәригать] кагыйдәләрен сайлап алып мин әзерләгән «Кавагыйд фикъһийә»мнең гаебе нидә булды икән? Шәйхелисламның карарында кулланылган гыйбарәләргә күрә, «Кавагыйд фикъһиядә» төзүченең «үз белдеге белән язылган нәрсәләр күп» имеш. Монысы дөрес – «Кавагыйд фикъһийә»дә минем тарафтан иҗтиһад кагыйдәсенә таянып карар кыйлынган һәм бу йөздән «үз белдеге белән язылган нәрсәләр» буларак кабул ителерлек ике нәрсә бар. <…> Беренчесе – риддәт*[1] *өчен җәза мәсьәләсе, икенчесе – ракъкыять*[2] *мәсьәләсе.*

*Әйе, беренче мәсьәлә буенча бәян иткән минем фикерләрем Мәшихат исламиянең*[3] *гасырлар дәвамында кыйлып килгәннәренә тулысынча каршы килә. Чөнки Госманлы дәүләте тарихында ил хакына үтә дә игелекле гамәлләр кыйлып, аңа карата турылыклы гомер итеп, фидакярләрчә хезмәт иткәннәрне үтерүнең йөзләгән, хәтта меңләгән мисаллары бар. Әмма риддәт кыйлып шәригатьне мәсхәрә иткән, иленә һәм ватанына хыянәт итүчеләрдән берсен генә булса да үлем җәзасына тарту мисалы Мәшихат исламия тарихында юк.*

---

[1] риддәт – диннән ваз кичү, динне алыштыру.

[2] ракъкыять – колбиләүчелек.

[3] Мәшихат исламия (Ислам шәехләре) – Госманлы дәүләтендә дин эшләре өчен җаваплы булган оешма, шәйхелислам һәм аның карамагында булган хезмәткәрләр.

*Әйе, мин риддәт кыйлган берәүгә салына торган җәзаны инкяр итәм. Тик, шул ук, вакытта, шәйхелисламнардан аермалы буларак, мин изге динебезне мәсхәрә кыйлучыларга һәм изге ватаныбызга хыянәт итүчеләргә карата мәрхәмәтле мөнәсәбәттә булу тарафдары да түгелмен.*

*Икенче мәсьәләдә, ягъни рәкъкыять мәсьәләсендә шәйхелисламнарның фәтвәләре белән минем фәтвам арасында шулай ук тәмам ачык аерма бар. Шуңа күрә минем карашымны «ялгышу һәм саташу» дип атарга шәйхелисламның хакы, әлбәттә, бар.*

*Моннан берничә дистә ел элек, Госманлы дәүләте биләмәләренә чиркәсләр күченгән дәвердә*[1] *дәүләт әһеленең «искитәрлек» карарлары (!) аркасында ул бичаралар Самсун һәм Трабзун вилаятьләрендә ачлыктан һәм хәерчелектән ишелеп-ишелеп кырыла башладылар. Олуг вәзир Гали Паша тарафыннан ул якларга юлланган махсус кешеләр шәйхелисламның шул чакта игълан ителгән фәтвәсен үтәү йөзеннән ата-аналарыннан мәхрум булып ятим калган кызларны Истанбул базарларында биш-алты куруш бәһасенә сатып, аларны җарияләргә әйләндереп фәхеш упкыннарына аталар иде.*

*Ел саен изге рамазан кичәләрендә аксөякләр сарайларына бүләк рәвешендә чиркәс яки грузин җарияләрне юллап тору гадәте, хөкемдарларны һәм аларның мәртәбәле кунакларын гүзәл көлиһәләр белән тәэмин итеп тору гадәте шул заманнан килә. Әгәр бу кабәхәтлекләр шәйхелисламнарның махсус фәтвәләреннән тыш кыйлынган булса да, ул кабәхәтлекләр, һичшиксез, аларның ярдәме белән һәм ризалыклары белән кыйлына иде. Хәлләрнең мондый рәвеше гадәти бер эшкә нәкъ менә Мәшихат исламиянең күз йомуы аркасында әйләнде. Сугышларда әсир ителгән кызлар Истанбулга китерелеп, шәйхелисламнар тарафыннан да, казыйлар тарафыннан да*

[1] 1817–1864 елларда Русиянең Кавказны яулап алу өчен Госманлы дәүләтенә каршы алып барылган сугышы нәтиҗәсендә җирле мөселман халыкларның, солтан химаясендә яшәр өчен, туган илләрен калдырып хилафәт биләмәләренә күченүләре күздә тотыла.

*«мөлке йәмин»*[1] *буларак кулланылалар иде. Төрекләр белән фарсылар арасындагы сугышларның берендә Надир-Шаһның хатыны әсир ителгән иде. Төркиянең олуг шәйхелисламының фәтвәсе белән ул ханым иң олуг төрек хөкемдарларының берсенә түшәк уенчыгы сурәтендә бирелгән иде.*

*Миллионлаган шундый вакыйгаларның без берничәсен генә искә алдык. Һәм, әгәр дә андый карарлар шәйхелисламнарның фәтвәлары белән рөхсәт ителә һәм мөмкин икән, минем «үз белдегем белән язганнарыма» күрә андый нәрсәләр һич тә ярамый һәм хәрамдер!» Бәлки нәкъ әнә шуңа күрә «мөлке йәмин» төшенчәсе белән акланган барлык шәйхелисламнарның фәтваларына һәм гамәлләренә каршы килгән минем сүзләрем «ялгышу һәм саташу», дип игълан ителде булса кирәк»*[2].

Шулай итеп, «*Кавагыйд фикъһийә*», беренче карашка, саф дини мәсьәләләргә кагылышлы хезмәт булып күренсә дә, аның эчтәлегендә мөселман җәмгыятенең чирләрен фаш итә торган, зурлап әйткәндә, яшәешнең иҗтимагый-социаль һәм әхлакый җитешсезлекләренә игътибарны җәлеп иттерә торган урыннар да булган. Бу аңлашыла да, чөнки Муса әфәнде гомере дәвамында фикъһы гыйлеменең, аның теориясе һәм практикасының хакыйкый тормыштан аерылган бер нәрсә булмыйча, мөселман җәмгыятенең цивилизацион-мәдәни вазгыятенә уңай тәэсир итә алуын һәм тәэсир итәргә тиешлеген дәгъвалаган.

Русия мөселманнары өчен шәригать журналын оештыру эше «*Кавагыйд фикъһийә*»нең басылуы белән, әлбәттә, тәмамланмый. Инде 1905 елда ук Оренбургта үткәрелгән Диния нәзарәте утырышында дин әһелләренең фикъһы буенча традицион әдәбияттан канәгать булмавы билгеле булса, 1910 елда «Шура» журналы әлеге фактка кабат игътибар иттергән. Әмма Бигиев матбугатта шәригать журналы әзерләнүе, бу саваплы эштә галим-голяманың киңәш вә ярдәменә, язмаларына ихтыяҗ барлыгы турында никадәр генә язса да, аңа уңай

[1] мөлке йәмин – сугышта яуланган мал, трофей мәгънәсенә ия булган шәригать (фикъһы) төшенчәсе.

[2] Китерелгән өземтә хәзерге татар теленә тәрҗемә ителде.

мөнәсәбәт белдерүчеләр, журнал төзүдә катнашырга теләк белдерүчеләр табылмый. Нәтиҗәдә, мондый битарафлыктан гарык булган Муса әфәнде «*Икенең берсе: йә үзең яз, йә үзеңә тәкъдим ителгәнне кабул ит!*» – дип җөпләп куя да, алга таба эшне үзе теләгәнчә дәвам итә[1].

## Финляндиягә беренче сәяхәте

1910 елның көз ахырларында Муса әфәнде Финляндиягә ике атналык сәяхәт кыла. Максаты ул чакта Русия империясенең бер өлеше булган бу төбәкне үз күзләре белән күрү һәм андагы халык, аның тормышы вә хәл-әхвәлләре белән танышу була. Шул сәфәреннән алган тәэсирләре турында түбәндәге хатирәләрен яза: «*1910 ел көз ахырларында күрмәк-өйрәнмәк нияте белән мин ике атна кадәр вакыт фин шәһәрләрендә йөргән идем.*

*Әүвәлге сәяхәтемдә минем күзем фин җирләренең табигый хәлләренә, ягъни һавасына, суларына, тауларына, ташларына, агачларына, урманнарына, күлләренә, чайләренә[2] бакмас иде. Бәлки сазлык, ташлык җирләрдә безнең татарлардан, руслардан, казаклардан күпкә рәхәт гомер иткән финнарның иҗтимагый хәлләренә, ягъни өйләрендә тормышларына, җиһазларына, пакьлекләренә; йортларда, кырларда, фабрикаларда, заводларда эшләренә-көчләренә; дүккәннәрдә[3], магазиннарда, базарларда сәүдәләренә, тиҗарәтләренә[4]; театрларда, кинематуграфларда, ресторааннарда, каһвәханәләрдә туплануларына-утыруларына; рухларына, ял сәгатьләрендә, бәйрәм көннәрендә урамнарда, мәйданнарда йөрүләренә, хәрәкәтләренә; кием-салымнарына, җәмгыятьләрдә[5], урамнарда хатыннарның-кызларның*

---

[1] Муса Бигиев. Кавагыйд фикъһийә // Шура. 1911. № 2. Б.43–45.

[2] чай – инеш, елга.

[3] дүккән – кибет.

[4] тиҗарәт – алыш-биреш, сәүдә.

[5] җәмгыятьләрдә – кешеләр җыелган җирләрдә, кеше күп булган урыннарда.

*әдәпләренә, хөрмәтләренә, назсыз-тәкәллефсез[1] хәрәкәтләренә, сүзләренә; урамларның, юлларның, йортларның һәр җирдә гаять пакьлегенә, башлангыч, урта мәктәпләрнең җәннәт биналары кебек матурлыгына-пакьлегенә, һичбер җирдә мәйханәләрнең, трактирларның, хәерче-ялангачларның юклыгына, кием-салымда фәкыйрьләрнең-байларның бәрабәрлегенә[2], урам башларында сакчыларның азлыгына, кәнисә[3] хәрәмнәрдә[4] финнарның әдәпләренә, хошугларына[5], эш сәгатьләрендә бакчаларның, мәйданнарның бушлыкларына, гомумән, баш күзе белән күренер иҗтимагый әхвәлләренә игътибар итә идем мин. Мин ул хәлләрен гаять бәгәнмеш идем[6].*

*Финнарны, гомумән, хатынларын-ирләрен, эш кешеләре [дип] булдым[7]. Эшләмичә көн күрү яки ялкаулык билгесе булган зәвыклы киемнәрне – ирләрдә, назлылык, эшсезлек күрсәткече [булган] ак-йомшак кулларны-бармакларны, мәүсем[8] модаларны хатыннарда күрмәдем. Руслар җәмгыятьләрендә мәүсем модаларын ригаять итмәмәк[9] гаептер. Әмма финнар күзендә модаларга иярмәү гаеп түгел, бәлки ялангачлар, фәкыйрьләр барында купшы-зиннәтле киемнәр кию гаептер кебек күренде. Шуңа күрә булса кирәк, финнарның байлары-фәкыйрьләре кием-салымда улкадәр аермалылык күрсәтмиләр. Финнарда киемнең кыйммәтлеге могътәбәр[10] түгел, бәлки пакьлек могътәбәрдер».*

1910 елда Финляндиягә сәфәрендә Муса әфәнде Һельсингфорс, Лаһтис, Або шәһәрләрендә гомер иткән татарлар белән күрешә, татар мәктәбе ачылышы тантанасында катнаша,

[1] тәкәллеф – ясалмалылык; кыйлану.
[2] бәрабәрлегенә – бергәлегенә, тигезлегенә.
[3] кәнисә – чиркәү-гыйбадәт
[4] хәрәм – изге урын, храм.
[5] хошуг – күңел түбәнчелеге.
[6] бәгәнмеш идем – хушланган идем, ошаткан идем.
[7] булдым – таптым, күрдем.
[8] мәүсем – ел фасылы, сезон; бәйрәм, тантана.
[9] ригаять итмәмәк – кайгыртмау, исәпкә алмау.
[10] могътәбәр – хөрмәтле, хөрмәт ителә торган.

дүртйөздән артык милләттәшләре алдында вәгазь сөйли. Гомумән, Финляндия дигәндә, Муса әфәнденең биредә яшәгән татарлар белән тыгыз дустанә мөнәсәбәттә булганлыгын истә тотарга кирәк. 1910 ел сәфәрендә дә, аннан соңгы елларда да ул җирле татар җәмәгатьчелеге өчен көтеп алынган кунак, зур дин галиме, остаз буларак каршы алынган, кунак ителгән, милләттәшләреннән кадер-хөрмәт, теләктәшлек һәм ярдәм күреп торган. Галимнең вафатыннан соң, 1950 елның 19 ноябрендә мулла Вәли-Әхмәт Хәким тарафыннан олуг галимгә багышланган «*Остаз шаһир*[1] *Муса Җаруллаһ хәзрәтләре хакында мөляхәзалар*» исемле хатирәләр китабы дөнья күрә. Шул рәвешле, Муса әфәндегә фин татарларының дини-иҗтимагый тормышларында һәм хәтерләрендә тоткан урынына үзенчәлекле һәйкәл куела. Моннан тыш, фин татарлары Муса әфәнденең вафатыннан соң, аның шәхси архивын, аерым алганда, китапларын һәм күпсанлы куен дәфтәрләрен саклап калуга һәм бу мирасны Төркиягә тапшыру эшенә үз өлешләрен кертәләр – 1979 елда галимнән калган бу хәзинә Төркия милли китапханәсенә ирешеп, әлегә кадәр шунда саклана.

## Фарсы шигъриятеннән тәрҗемә

1910 елда Муса әфәнденең «***Диваны Хафиз тәрҗемәсе***» дип аталган тагын бер күләмле һәм жанры ягыннан үзенчәлекле гыйльми-әдәби хезмәте дөнья күрә[2]. Бу әсәр – миладичә 1321–1389/1390 елларга гомер иткән бөек фарсы шагыйре Шәмсетдин Мөхәммәт Хафиз Ширазиның иҗат җимеше. Әлеге җыентыкка 5–10 бәеттән торган 418 газәл, 29 кыйтга, 41 робагый, 5 касыйдә һәм «*Киек ана болан*», «*Сәкый-намә*» һәм «*Мөганни-намә*» исемле күләме зур булмаган өч мәснәви керә. «Диван» дигән гарәп сүзе исә «шигъри әсәрләр җыентыгы» мәгънәсенә ия.

---

[1] шаһир – атаклы, шөһрәтле, мәшһүр.

[2] Бигиев М. Диван-ы Хафиз тәрҗемәсе. Казан: «Үрнәк» матбагасы, 1910. 145 б. Бу китапның икенче басмасы 1912 елда Казанда Л. И. Антонов электро-типографиясендә нәшер ителә.

Фарсы шигъриятендә камиллеге белән иң югары дәрәҗәгә ирешкән әсәр буларак танылган «Диван»ны Муса әфәнденең татар теленә тәрҗемә итүе үзе бер әдәби каһарманлык, кыю бер иҗади адым булып тора. Әлеге эшкә алынуы сәбәпләрен аңлатып, ул болай дип язган: «*Галәме исламияттә иң мәшһүрләрдән хуҗа Шәмсетдин Мөхәммәд Хафиз Ширази хәзрәтләре Иран шагыйрьләренең иң бөекләреннән иде. Әдәби гыйльми шигырьләре чук*[1] *имеш исә дә, үз каләме белән тәэлиф кыйлынмадыгыннан, галәме әдәбиятта шигырьләренең һәммәсе мәхфуз уламамыш*[2]. *Хуҗа Хафизның могътәкыйдләреннән*[3] *сәйид Касим Әнвар хәзрәтләре Хафизның шигырьләрен кусурсыз*[4] *иҗтиһад*[5] *белән җәмыг итеп*[6], *фарсы әдәбияты галәмендә иң мәшһүр «Диваны Хафиз»ны тәртиб итмештер*[7]. *Ул әдәп хәзинәсе булган «Диван» Аурупа лисаннарының*[8] *әксәренә*[9] *тәрҗемә кыйлынмыш, Дәүләт госмания голямасы, өдәбасы*[10] *да, ул диванның шигырьләренә мәфтүн булып*[11], *гүзәл тәрҗемә, гыйльми шәрехләр язмышлар.*

*Мин дә Русиядә рагбәтле*[12] *таләбәләрнең истифадәләренә*[13] *гарыз итмәк*[14] *фикре белән бу Диванның иң гүзәл, иң хикмәтле гыйльми шигырьләрен интихаб кыйлып*[15], *«һәрбер*

---

[1] чук – күп.

[2] мәхфуз уламамыш – саклана алмаган; сакланмаган.

[3] могътәкыйд – нык инанучы;

[4] кусур – кимчелекләр, җитешсезлекләр.

[5] иҗтиһад – биредә: гыйльми тырышлык, эшне җиренә җиткереп эшләү.

[6] җәмыг итеп – җыеп, туплап.

[7] тәртиб итмештер – тәртипкә салган; эзлекле хәлгә китергән.

[8] лисан – тел.

[9] әксәренә – күпчелегенә.

[10] өдәба – әдипләр.

[11] мәфтүн булып – сокланып; баш әйләнеп.

[12] рагбәт – нык теләк; омтылыш.

[13] истифадә – файдалану, куллану.

[14] гарыз итмәк – тәкъдим итү.

[15] интихаб кыйлып – сайлап алып.

*бәет үзәренә ялңыз[1] бер генә сәтыр[2] мәгънә бирмәк» ысулы белән тәрҗемә язып, әледән-әле бер файда зиядә итмәк[3] арзусы[4] белән «юк-бар» шәйләрне[5] дә каййид итеп[6], «Шәрыкъ» сахибы[7] Әхмәд әл-Исхакый нәфәкасы[8] белән бу тәрҗемәне нәшер иттем.*

*Киләҗәкдә әдиб улурым! Һиммәте белән әдәбиятны иҗтиһад белән мөталәга идәнләр[9], йахуд һәрбер хосусда үзенә мөнасиб иң хикмәтле бер бәетне мисал юлында сөйләмәк икътидарына рагбәт идәнләр[10], яисә «иске асар исламиядә ниләр бар икән? арзусы белән әхъйанән[11] әдәбийат исламияне дә кулларына алганнар, һәм дә «*كالمفاتح عند باب لا يغنى كتاب عن كتاب وكل*»[12] игътикады белән китапларның һәрберенә ихтирам күзе белән назар идәнләр[13], бу китаптан да беркадәр файда алсалар кирәк. Гомумән, тагын да кыска бер сүз белән әйтим: мөселманлар күзендә әдәби шәйләрнең игътибары арткан саен, мондый китапларның файдасы арта булса кирәк».*

«*Диван-ы Хафиз*»ның Муса әфәнде тарафыннан ясалган тәрҗемәсе бүгенге көндә әдәбият тарихы, әдәбият белеме, әдәби тәрҗемә, татар тәрҗемә тарихы, тел белеме кебек фәннәр белән шөгыльләнүчеләрнең игътибарын, әлбәттә, җәлеп итәргә лаеклы.

1910 елда Муса әфәнде Андалуслы дин галиме имам ибне Фирруһ әш-Шатыбиның (милади 1194-тә вафат) Коръән

[1] ялңыз – бары тик; ялгыз.

[2] сәтыр – язма юл.

[3] зиядә итмәк – арттыру, кушу.

[4] арзу – теләк.

[5] шәй – нәрсә, әйбер.

[6] каййид итеп – теркәп, язып.

[7] сахиб – хуҗа; ия.

[8] нәфәка – акчалата чыгымнар.

[9] мөталәга идәнләр – укыганнар; укып баручылар.

[10] рагбәт идәнләр – ныклап теләгәннәр.

[11] әхъйанән – әледән-әле.

[12] тәрҗемәсе: Һичбер китап башка китапны алыштырмас, һәм һәр китап капка ачкычы кебектер.

[13] назар идәнләр – караганнар; караучылар.

айәтләренең санын һәм аларның башын-ахырын тәгаенләүгә багышланган «***Назымәту әз-зүһр ли-имами Аби Мөхәммәд әл-Касим ибни Фирруһ әш-Шатыйби радыйа Аллаһу ганһу***»[1] исемле гарәп телендә язылган китабына шәрех язып, кыска гына кереш сүз белән шундый ук соңгы сүз (эпилог) кушып бастыра. Эпилогта Муса әфәнде үзенең бу хезмәтен әлеге «*Назымәтү әз-зүһр*»гә язылган беренче шәрех буларак билгеләп уза.

Шул ук елда Муса әфәнде имам әш-Шәһразуриның[2] хәдис гыйлеменә фундаменталь кереш хезмәт рәвешендә язылган «Мөкаддимәт Ибне Салях» исемле китабына имам Ибне Хаҗәр әл-Гаскаляни тарафыннан язылган «*Нөхбәт әл-фикр*» исемле мохтасарга (кыскартылган күчермәгә) шәрех сурәтендә иҗат ителгән «***Нүзһәтүән-натъри фи тәүдыйхи нөхбәти әл-фикри***» исемле хезмәтен бастырып чыгара[3].

Муса әфәнде зур игътибарын Андалуслы дин галимнәренең иҗатына багышлаганга күрә, бу Андалус (әл-Андалус) дигән сүзгә дә тукталып алыйк. Хәзерге вакытта, Испаниянең көнчыгышында урнашып, үз эченә сигез провинцияне алган Андалусия исемле тарихи-мәдәни бер өлкә бар. Башкаласы Севилья шәһәре. Андалусия сүзе исә – гарәп теленнән кереп калган: әл-Андалус милади VIII–XV гасырларда Иберия ярымутравында чәчәк аткан мөселман цивилизациясен белдерә. Бер риваятьтә әл-Андалус сүзе Нух пәйгамбәр токымыннан булган Андалус бин-е Тубалга бәйле, икенче бер риваятькә караганда, гарәпләрнең диңгез аръягында урнашкан җирләрне «биләд әл-вандалүс» (вәхшиләрнең илләре) дип атауларыннан килеп чыккан.

Милади 713 елда Африкадан үтеп кергән мөселманнар бу ярымутрауны тулысы белән диярлек яулап алып, хәтта

[1] Назымәтү әз-зүһр ли-имам Аби Мөхәммәд әл-Касим бин Фирруһ әш-Шатыйби разыйа Аллаһу ганһу. Оренбург: Тип. Газ. «Вакъ», 1910. 112 б.

[2] Әш-Шәһразури (Әбу Гамр Госман ибне Габдеррахман Саляхетдин әл-Көрди әш-Шәһразури (1181–1245) – Ибн әс-Салях исеме белән көрд фәкыйһы, танылган хәдис гыйлеме белгече.

[3] Нүзһәтү ән-натъри фи тәүдыйхи нөхбәти әл-фикри. Оренбург, 1910.

Пирәнәй тауларын үтеп, хәзерге Франция җирләренә дә һөҗүм итәләр. Әл-Андалусны яулау шактый тыныч рәвештә, җирле хөкемдарларның Димәшыктагы хәлифә хакимиятен танулары турындагы килешүләр кору ысулы белән башкарыла. Нәтиҗәдә ул хөкемдарлар мал-мөлкәтләрен дә, үзләренең диннәрен дә саклап калалар. Биредә яшәгән яһүдләр һәм христианнар, ислам халифәтенең башка вилаятләрендәге кебек, *зиммиләр*, ягъни мөселманнар химаясе астында яшәүче әһле китаб буларак гомер итәләр. Мөселманнарның җирле халыкны диннәреннән көчләп, кан коеп аермавы, дин ирегең саклавы җирле халыкның күпчелегенең күңелләрен яулый. Нәтиҗәдә бик күп халык ислам динен кабул итеп, мөселман өммәтенә кушыла.

Бу кадәр төрле мәдәниятләрнең янәшә булуы, бер-берсен баетуы, кушылуы Әл-Андалуста тиңе булмаган югары дәрәҗәле ислам мәдәнияте барлыкка килүенең нигезендә ята. Әл-Андалус мөселман мәдәниятендә гаҗәп күп галимнәр, фәкыйһләр, фән эшлеклеләре, фикер ияләре, суфилар, язучылар, шагыйрьләр, архитекторлар, сәнәгатьчеләр җитешә. Муса әфәнде үзенең гыйльми эшчәнлегендә бу төбәктә иҗат иткән галимнәрнең күптән онытылган, әмма һаман да әһәмиятләрен югалтмаган әсәрләрен яңадан өммәт даирәсенә кайтару белән юкка гына шөгыльләнмәгән.

Искә алынган елларда Муса әфәнденең актив сурәттә татар вакытлы матбугатында мәкаләләр бастырып торуы мәгълүм. Андыйларның саны дистәләгән һәм аларны барлауга багышланган фәнни эш башкаручысын көтеп кала. 1910 елдан башлап Муса әфәнденең мәкаләләре Госманлы вакытлы матбугатында да чыга башлый. Хәзерге вакытта кулыбызда булган мәгълүматка таянып әйткәндә, аның Төркиядә басылган беренче мәкаләсе «Тәгаруфы мөслимин» журналында «*Шәригать исламия хөрмәтенә бер риҗа*»[1] («Ислам шәригатенә ихтирам йөзеннән бер үтенеч») исемле ачык хаты була. Әлеге язма башта «Йолдыз» гәзитенең 14 сентябрь санында чыга, аннары «Вакыт» гәзитенең 16 сентябрь санында кабат

[1] Муса Бигиев. Шәригаты исламия хөрмәтенә бер риҗа – Ачык мәктүп // Тәгаруфы мөслимин. 29 Үктәбер 1910. 301–302 б.

басыла һәм, күрәсең, Төркиядә «Тәгаруфы мөслимин» («Мөселманнарны үзара таныштыру») журналын чыгаручыларның да игътибарын җәлеп итәрлек дәрәҗәдә кызыклы яки әһәмиятле булып чыга. Мәкаләдә сүз «*Әхкям шәргыя мәҗәлләсе*» («Шәригать хөкемнәре журналы») исемле журнал чыгаруга әзерлек башлануы, аның максатлары, эчтәлеге, үзенчәлекләре турында һәм бу хосуста әйтер сүзе булган фикъһы белгечләрен катнашырга чакыру турында бара. Ягъни Русиядә шәригать журналы булдыру мәсьәләсе Госманлы матбугатында да яктыртылган булып чыга.

1910 елда Русия татар матбугатында Муса әфәнденең исеме татар милли тарихы сәхифәләренә рәсми рәвештә теркәлә: Шәрәфетдин әфәнде Шәһидуллин[1] үзе төзегән «*Заман календаре*»ндә яшь дин галименә багышлап «*Муса әфәнде Бигиев*» исемле биографик белешмә урнаштыра.

## Аллаһ мәрхәмәтенең гомумилеге турындагы хезмәтләре

1911 елда Муса әфәнде «Хөсәения»дә укыткан диннәр тарихы дәресләрен «Шура» журналында бастырып бару белән генә чикләнмичә, әлеге идеяләрне «***Рәхмәт илаһийә борһанлары***»[2] («Илаһи мәрхәмәтнең инкяр ителә алмаслык дәлилләре») белән «***Инсанларның гакыйдә илаһийәләренә бер назар***»[3] («Кешеләрнең илаһи инануларына бер караш») исемле ике китап рәвешендә бастырып чыгара. Алар Русия мөселман җәмәгатьчелегенә генә түгел, хәтта Госманлы Дәүләти Галиясенең әһле исламнарына ирешеп, андагы фикер хәрәкәтенең җанлануына этәргеч була.

---

[1] Шәрәфетдин Шәһидуллин (Кәшшафетдин улы Шәрәфетдин Шәһидуллин, 1879–1942) – нашир, журналист, эшмәкәр һәм мөхәррир, «Заман календаре»ннән тыш, «Игълянат» гәзите һәм «Русия сәүдәсе» журналы мөхәррире булган.

[2] Муса Бигиев. Рәхмәт илаһийә борһанлары. Оренбург: «Вакыт», 1911. 97 б.

[3] Муса Бигиев. Инсанларның гакыйдә илаһийәләренә бер назар. Оренбург: «Вакыт», 1911. 26 б.

Әлеге ике хезмәтнең рухи, мәгънәви, әхлакый, дини әһәмияте әйтеп-аңлатып бетергесез дәрәҗәдә бөек.

Мәгълүм ки, татарлар күп гасырлар дәвамында Русия хакимияте астында яшәргә мәҗбүр булсалар да, бәйсез иректә тормыш турында хыялланганнар. Бу нисбәттән, Аллаһ мәрхәмәтенең гомумилеген дәгъвалавы белән Муса әфәнде мөселман замандашларына бер дәүләт мохитендә төрле халыклар белән тату яшәүнең мөмкинлеген һәм тиешлеген ислам тәгълиматының катгый хөкемнәренә таянып күрсәтергә теләгән.

Ләкин Аллаһның киң рәхмәте белән һәркемнең дә коткарылачагы турындагы идея милләттәшләренең йөрәкләрен парә-парә телгәли, акылларын чуалта, хисләрен ярсыта. Моны аңлап та була, чөнки дәүләтчелекне, ирекне югалтканнан соң, татар кешесе өчен бердәнбер юаныч булып җәберләнгән вә кимсетелгәннәргә – җәннәт, җәберләүчеләр вә кимсетүчеләргә мәңге дәвам итәчәк тәмуг газапларын вәгъдә итеп торучы дин кала. Мондый шартларда Аллаһка турылыклы булып игелекле гамәл кылуны диндарлыкның асыл билгесе итеп күрсәткән Коръән тәгълиматы томалана, диндарлык билгесе рух вә әхлак кебек нигезләреннән кузгалып, этно-конфессиональ һәм сәяси-иҗтимагый мөнәсәбәтләр яссылыгына күчә. Шулай итеп, татар күзаллавында татар булу – диндар булуның, Аллаһ ризалыгына ирешеп, киләчәктә оҗмах иясе ителүнең бердәнбер шарты буларак кабул ителә башлый. Бу хәлдә, киләчәктә Аллаһ тәгалә барлык кешеләргә оҗмах капкаларын ачачак дип игълан итеп, һәм бу карашка Коръән һәм Сөннәттән дәлилләр китергән Муса әфәнденең чыгышы аяз көнне суккан яшендәй кабул ителә. Бу чыгыш кяферләрне көтеп торган котылгысыз газапларны күзаллап юанган мөселманнарның катгый рәвештә җәннәткә кертеләчәкләре турындагы самими инануларын какшата, ул инануларның нигезсез булуын, Коръәнгә туры килмәвен фаш итә. Үзләрен мөселман булганга күрә генә көткән бәхетле Ахирәт турындагы хыялларының җимерелүенә татар мөселман җәмгатьчелеге, әлбәттә, әзер булмый, Муса әфәнде яңгыраткан идеяләр ар-

касында башланган ифрат та киеренке психологик драмадан зыян күрмичә, элекке хәлдә калу, вөҗдан тынычлыгын югалтмау чараларын да таба алмый интегә. Нәтиҗәдә, тынычлыкны югалттырган Муса әфәндегә халыкның бер өлеше тәкфир һәм ләгънәт яудыра.

Кушымтада искә алынган «*Рәхмәт илаһийә борһанлары*» исемле әсәрдән әлеге чын мәгънәдә тирән һәм мөһим темага караган берничә парча китерәбез[1].

## Бәрәкәтуллаһ белән күрешүе

1911 елда Петербургка Муса әфәнде белән Һиндестанда укыган чагында танышып калган, бергәләп дин сабагы алган күптәнге дусты – зур дин галиме, шагыйрь һәм җәмәгать эшлеклесе Мәүләви Бәрәкәтуллаһ Сахиб[2] әфәнде килеп төшә. Муса әфәнде бу танышлыгы турында болай дип язган: «*Һиндестанның бөек остазларында бергәләп сабак алган булуыбыз аркасында, мин дә аның дусты булу шәрәфенә ия идем*».

Ул елларда Бәрәкәтуллаһ әфәнде зур сәфәргә чыккан була: башта ул Токионы зиярәт итә, аннары Төркиядә 1908 елда булып алган инкыйлаптан соңгы хәлләр белән танышыр, күптәнге дуслары белән күрешер өчен Истанбулга килеп төшә һәм, ниһаять, Русиянең башкаласы – Петербургка юл тота. Бәрәкәтуллаһ әфәнде Муса әфәндедә атна-ун көн кунак

[1] Карагыз: III Бүлек. 3: «Рәхмәт илаһийә борһанлары»ннан.

[2] Мәүләви Бәрәкәтуллаһ Сахиб (Мөхәммәд Бәрәкәтуллаһ Бхопали; 1854–1927) – Һиндестанның танылган дин галиме, шагыйрь, җәмәгать эшлеклесе, Һиндестанның бәйсезлеге өчен барган көрәш вәкиле, ялкынлы инкыйлабчы, панисламистик хәрәкәт вәкиле. Һиндестаннан читтә яшәгән дәвердә Көнбатышның прогрессив газеталарында илнең бәйсезлеге өчен ялкынлы революцион мәкаләләр белән чыгыш ясап, сәяси көрәшен дәвам итә. 1915 елда Әфганстанда оештырылган Һиндестанның беренче Вакытлы хөкүмәтендә премьер-министр була. 1927 елда Сан-Францискода вафат була. 1988 елда Бһопал университеты Бәрәкәтуллаһ университеты исемен ала. Аның исеме белән бергә телгә алына торган мәүләви, сахиб кебек сүзләр аның дәрәҗәсен һәм үзенә карата булган ихтирамны белдерә.

була, дуслар бергәләп шәһәрне гизәләр, андагы музейларны, тарихи урыннарны тамаша итәләр, төрле темаларга сохбәтләр коралар, мөселманнар белән очрашулар үткәрәләр. Бу очрашу турында Муса әфәнде мондый хатирәләр язып калдырган: «*Беркөн Ленинградның*[1] *зур кәнисәсе – София соборында Мәсихнең*[2] *табуты янында бераз тордык. Бу зур табутны күргәненә күрәдер, бәлки, [Бәрәкәтуллаһ әфәнде]* (وَمَا قَتَلُوهُ وَمَا صَلَبُوهُ)[3] – (يَقِينًا بَل رَّفَعَهُ ٱللهُ إِلَيْهِ وَمَا قَتَلُوهُ)[4] *дигән айәт кәримәләр хакында бик тә сәер фикерен белдерде. Мәсихнең үтерелүе хакында яһүдләрнең дәгъваларына, насараларның*[5] *гакыйдәләренә туры килгән карашы белән уртаклашты. «Тәфсир кәбир»дә Коръән кәрим айәт кәримәләренә туры килмәгән каршылыклардан, Әбү Мөслим әл-Исфаһани*[6] *кебек мөфәссирләрнең*[7] *аңлатуларыннан, 4 нче томдагы 3 нче рисаләдә*[8] *Мәсихнең үтерелүе һәм хачка асылуы хакында «Ихван әс-сафа»*[9] *кебек китапның ачык аңлаешлы бәяннарыннан,*

[1] Хатирәләр Муса әфәнденең 1933 елда, ягъни шәһәр Ленинрад исемен алганнан соң чыккан китабыннан алынды.

[2] Мәсих – христиан динендә Гайсә пәйгамбәрнең ләкабы, ягъни, титулы; Помазанник.

[3] «Алар аны ни үтермәделәр, ни хачка асып куймадылар» (Коръән, 4:157).

[4] «Алар аны тәгаен генә үтермәделәр, әмма Аллаһ аны Үзе янына ашырды» (Коръән, 4:157).

[5] насаралар – тумышы белән Насарат (Назарет) шәһәреннән булган Гайсә пәйгамбәр галәйһиссәламнең сәхабәләре.

[6] Әбү Мөслим әл-Исфаһани (868–934) – тел гыйлеме белгече, әдәбиятчы, дин галиме, мөфәссир, габбасыйлар хөкүмәтенең күренекле вәкиле.

[7] мөфәссир – Коръәнне тәфсир итүче (тәфсилләп аңлатучы) дин галиме.

[8] рисалә – язма, мәкалә; әсәрнең бүлеге; әлеге сүз рисаләт сүзеннән бернәрсәсе белән дә аерылмый, әмма татар телендә аның ике төрле язылышы ярдәмендә бер-берсеннән үзгә булган ике мәгънәне чагылдырып була.

[9] «Ихван әс-сафа» («Сафлык бертуганнары», тулы исеме «Ихван әс-сафа вә хуллән әл-вафа вә аһл әл-гадел вә әбнаъ әл-хәмед») – X йөздә Гыйракта фикердәшләр тарафыннан оештырылган яшерен

*«Гаһед җәдид»нең шәрехләрен*[1] *дәвамлы укуларыннан илһам алыптыр, бәлки, мәүләви Бәрәкәтуллаһ болай диде: «Коръән кәримдә инкяр ителгән вакыйга хачка асылу вакыйгасы булмыйча, бәлки мәлгун*[2] *булганга күрә Мәсихнең хач җәзаларына дучар ителгән булуы турындагы шикләнүдер. Ягъни, хачка асылган булса, ул мәлгунь булмады, бәлки, яһүдләрнең дөрес булмауларын күрсәтү өчен Аллаһ хозурына ашырылды».*

(وَلَا تَحْسَبَنَّ الَّذِينَ قُتِلُواْ فِي سَبِيلِ اللهِ أَمْوَاتًا)[3] *дигән айәт кәримә дә шәһитләрнең җәсәдләренең үтерелгән булуын һәм мәет булуын инкяр итми. Аллаһ юлында, идеал юлында үтерелгән кеше үле булмас, бәлки күкләргә, бәлки Аллаһ Җәллә җәләлүһү хәзрәтләренә сәфәр итә, күтәрелә димәк кебек бер бәяндыр», – диде.*

*«Тәфсир кәбир»ләрдәге каршы чыгуларны, Исфаһаниләрнең, «Ихван әс-сафа»ларның бәяннарын белә идем. Бу йөздән мәүләви Бәрәкәтуллаһ фикерен дә зур теләк белән тыңладым. Мондый мәсьәләләрдә әһәмиятле, хөрриятле фикерләрне мин һәрвакыт хуплыйм. Ләкин Мәсих ибне Мәрьям хакында минем карашым имам Разиләрнең, Исфаһаниләрнең, Бәрәкәтуллаһларның карашларыннан бөтенләй үзгәдер. Нәбиләрне үтерү, үтерелгәннәрне хачка асып кую яһүд тарихында гади бер хәлдер. Хисабы юк нәбиләрне үтергән, үтерткән яһүдләр Гайсәне үтергәнгә нигә шулкадәр горурланырга тиешләр ди? Әһәмияте аз булган гади, гадәти бер вакыйга хакында яһүднең файдасыз горурлыкларын, ялган дәгъваларын Коръән кәрим шулкадәр олы игътибар белән ни өчен фаш итте? Моңа нинди мәгънә салынган? Моның нинди сере бар? Хикмәте нидер?*

---

җәмгыять. Катнашучыларның максаты иҗтимагый тормышны җайга салу өчен дин, әдәп-әхлак, фәлсәфә, сәясәт һәм фән даирәләренә караган мәсьәләләрне хәл итү булган.

[1] шәрех – нинди дә булса бер әсәрдә әйтелгәннәрне яхшырак аңлату, ачыклау өчен язылган махсус әсәр.

[2] мәлгун – ләгънәт кыйлынган берәү.

[3] «Аллаһ юлында үтерелгәннәрне мәетләргә санама» (Коръән, 3:169).

*Фикерләрем берничә ел дәвамында шушының белән мәшгуль булды. Ниһаять, калебемдә куәтле бер канәгатьләнү хисе хасил булды да, «Коръән кәрим айәт кәримәләренең могъҗиз[1] ифадәләренә күрә Мәсих ибн Мәрьям»[2] дип аталган кыска гына бер рисалә яздым».*

## Финляндиягә икенче сәяхәте. Баемаган кояшны күзәтү

Шул ук 1911 елның июнь аенда Муса әфәнде якын дусты имам Лотфулла хәзрәт Исхаков белән бергәлектә икенче мәртәбә Финляндиягә сәфәр чыга. Бу юлы аның максаты Финляндиянең төньяк өлеше аркылы узган Котып хаттына[3] кадәр барып җитеп, шунда төн уртасында баемаган кояшны күзәтү була. Әлеге сәфәр нәтиҗәсендә гыйльми иҗатының йөзек кашыдай кыйммәтле булган чираттагы әсәре – «***Озын көнләрдә рузә***»[4] («Озын көннәрдә ураза») дигән фәтва китабы языла. 208 сәхифәле бу китап, һаман да шул ук 1911 елда Казандагы «Өмид» басмаханәсендә чыгып, Русия һәм Госманлы мөселман матбугаты сәхифәләрендә татар галименең әсәрләренә карата шаулап торган кызу полемик туфанга яңа көч бирә.

Бу китабында Муса әфәнденең асыл максаты җәйге озын көннәрдә җир шарының шәфәкъ яктысы бетми торган яки ак төннәр күзәтелә торган кыйтгаларында ураза тотуның тиеш булмавы турында фәтва чыгару була. Шушы фәтваны нык шәргый нигезгә урнаштыру йөзеннән, ул сүзне бик еviews ерактан башлый. Нәтиҗәдә, китап, бер яктан, үзенең һәр сәхифәсе белән әлеге фәтваны дәлилләүгә багышланган булса, икенче яктан, шул дәлилләүгә хезмәт итүче гаять күп янәшә торган мәсьәләләр кузгатыла. Мәсәлән, Муса әфәнде Идел буе мө-

---

[1] могҗиз – могъҗизави, гаҗәеп, искитәрлек; шаккаттырырлык.

[2] Муса әфәнденең 1933 нче елда Берлинда чыккан китабы.

[3] Котып хатты – елның иң озын көннәре дәвамында баемыйча хәрәкәт иткән кояшны күреп булган географик гарыз (Төньяк ярымшарның $66^{1/2}$ дәрәҗәсенә туры килә).

[4] Муса Җаруллаһ Бигиев. Озын көнләрдә рузә. Казан: Электро-Типография «Умид», 1911. 208 б.

селманнарын борынгы заманнардан, хәтта Болгар дәвереннән үк борчып торган якты төннәрдә ястү намазын уку-укымау мәсьәләсен бик җиңел һәм мантыйклы сурәттә хәл итә, Коръән айәтләрен нәсех кылуның (ягъни айәтләрне гамәлдән чыгаруның) дөрес булмавын, моның белән шөгыльләнгән голяманың ялгышуларын җиренә җиткереп дәлилли.

Автор тарафыннан игътибарга алынган кайбер мәсьәләләр, беренче караштa, асыл максаттан шактый ерак булып күренсәләр дә, нигездә алар да якты төннәрдә ураза тоту мәсьәләсенә караган төп фәтвага теоретик нигез салуга хезмәт итә. Андыйлардан инде искә алынган фин илендә сәфәр турындагы язмалар гына түгел, хатын-кызның кабыргадан яратылганлыгы, аның ир-аттан һәрьяклап түбән һәм зәгыйфьлеге, Адәм галәйһис-сәламнең җәннәттән хәлал җефете Хәүва аркасында куылган булуы турындагы һәм, болардан тыш, ислам рухына туры килмәгән башка борынгы инануларны, чынлыкта исә – хорафатларның Муса әфәнде тарафыннан тәнкыйтькә тотылып тар-мар ителүләрен атап була. Кыскасы, әлеге «*Озын көннәрдә рузә*»нең эчтәлеге нибары бер максатка ирешүне күздә тотса да, автор бу әсәренә тирән фәлсәфи мәгънә белән бергә кеше аңын уятырлык бихисап мәгълүмат, мөстәкыйль һәм ирекле фикерләүнең бәрәкәте турындагы үгетләүләрен, диндә дөреслекне ялгышлардан аерырга өйрәнү ысулларын һәм башка бик күп нәрсәләрне сыйдыра алган. Муса әфәнденең бу китабыннан аның Финляндиягә сәяхәте турындагы бүлекне кушымтада тәкъдим иттек[1].

Зәки Вәлиди Муса әфәндегә кагылышлы бер язмасында 1911 елда аның «***Сионизм***» исемле күләмле әсәре чыккан булуы турында хәбәр итә[2]. Бу китап әлегә кадәр табылмады, мөгаен ул басылмаган да булгандыр яки аның басылган елы башка булуы ихтималы да бар. Бу соңгы фикерне 1913 елда «Вакыт» гәзите сәхифәләрендә басылып чыккан «*Си-*

---

[1] Карагыз: III Бүлек. 4: Сәхәр кояшы.

[2] Zeki Velidi Togan. Musa Cârullah Begi’nin Hayatı ve Eserleri Selâmet. Sayı: 5. Cilt 105. Sayı (23 Kasım 1949). 2, 5–7 s.

*онизм I*»[1], «*Сионизм II*»[2] һәм «*Сионизм мөнәсәбәтейлә*»[3] исемле өч мәкалә куәтли. Беренче мәкаләдә Муса әфәнде, ул көннәрдә бик көчәеп киткән сионизм мәсьәләсен игътибар үзәгенә алып, яһүдиләрнең тарихлары һәм киләчәкләре турында бәян кылган Коръән айәтләрен тәфсир итә. Икенче һәм өченче мәкаләдә, XIX йөзьеллыктан башлап, сионизм тарихы бәян ителә.

## Муса Җаруллаһ һәм Габдулла Тукай

1912 ел, беренче нәүбәттә, Муса әфәнденең Габдулла әфәнде Тукай белән якыннан аралашып алуы белән истәлекле.

Милләтебезнең хәтере түрендә урын алган кадерле затыбыз, татар күңелендәге моңны шигъри сүз белән нәкышләп дөньяга ишеттергән олуг шагыйребез Габдулла Тукай белән олуг дин галиме һәм җәмәгать эшлеклесе булган Муса әфәнде Бигиев очрашмаган, аралашмаган булсалар, бәлки сәер дә булыр иде. Әмма алар аралашканнар да, көрешкәннәр дә. Һәм ике олпат зат арасындагы бу мөнәсәбәт, дөресен әйткәндә, Тукай тарафыннан корыла башлый. Моның чыннан да шулай булуын аңлар өчен югарыда искә алган «*Зур бәшарәт*» (1909) исемле шигырьне искә төшерү дә җитә. Әмма Тукай тарафыннан Муса әфәндегә атылган бу сатира уклары беренче булмый. Шагыйрь Муса әфәндене «чеметкәләвен» инде 1908 елда «Яшен»[4] сәхифәләрендә чыккан язмаларыннан башлаган була. Анда Тукай Муса әфәнденең, мөселман булуына карамастан, тышкы кыяфәте белән христианнарга охшавына тел тидерә, абыйсы Мөхәммәт-Заһирның әдәби романнарын нәшер итмәве өчен шелтәли. Бу шелтәләвен Заһир Бигиев белән төшендә «булган» әңгәмәгә нигезли. Заһир Тукайдан язып калдырган ике әсәренең басылып чыгуы-чыкмавы турында сораган, имеш. Тукай исә җавап итеп: «Синең кардәшең Муса Бигиев үзенең

[1] Муса Бигиев. Сионизм I // Вакыт. № 1254 (20 июль 1913).

[2] Муса Бигиев. Сионизм II // Вакыт. № 1261 (28 июль 1913).

[3] Муса Бигиев. Сионизм мөнәсәбәтейлә // Вакыт. № 1266 (3 август 1913).

[4] «Яшен» – 1908–1909 елларда Казанда чыккан сатирик журнал. Баш редакторы Галиәсгар Камал (1879–1933) була.

һич кирәксез тәҗвидләрен һәм башка борынгы китапларны атна саен бастырып тора, әмма сезнең китапларга килгәндә сабырлык белән эш итә», дигән. Моны ишеткәч Заһир әфәнде энесенә карата ризасызлыгын сиздерми кала алмаган, имеш. 1910 елда «Ялт-йолт»[1] журналының июль ае саннарында басылган «*Фәлсәфи сүзләр*» исемле тагын бер мәкаләсендә үзен «Фәйләсүф» дип имзалаган Тукай Муса әфәнде күтәреп чыккан илаһи мәрхәмәтнең гомумилеге мәсьәләсенә киная кылып, ул илаһи мәрхәмәтнең аз гына булса бер өлешен мәрхүм агасы Заһирга насыйп итү йөзеннән, аның «Катилә» һәм «Мөртәд» исемле әсәрләрен бастырып чыгаруда да тырышлык күрсәтмәвенә ризасызлыгын сиздереп, болай дип язган: *««Рәхмәт-е илаһийә гомуми»дер. Ләкин М.ә.Б. мәрхүм Заһир әфәнде рисаләләренә нидәндер шул гомуми рәхмәттән бер тамчы да тиермидер. Ул рисаләләргә дөньяга чыгуга ирек бирмичә, һаман әгъраәфта тотадыр. Халык исә «Катилә» белән «Мөртәд»нең киң рәхмәте илаһийә сәйасендә азат ителәчәген көтәдер*»[2].

Гаҗәп, әмма Муса әфәнде, шагыйрь аны көлкегә калдырга тырышса да, рәнҗемәгән, үчекләшмәгән. Киресенчә, аңа карата ихтирамын белдереп торган. Мәсәлән, 1911 елда нәшер ителгән «*Рәхмәт илаһийә борһанлары*» исемле китабында Тукайның түбәндәге шигъри юллары эпиграф буларак файдалана:

*Дустларым кардәшләрем! Сез меллаларга әйтеңез:*
*Шу ике юлны мине күмгәч укырлар каберемә.*
*Әһле тәкфир бер гаҗәпләнсен күреп актык сүзем:*
*«Күр, нә рәсмә тулган иман илә Коръән садырыма!»*[3]

Һәм әлеге юлларның авторына карата олы ихтирамын белдереп, эпиграфтан соң мондый сүзләр язып куя: «*Шагыйрь миллиемез, әдиб мөхтәрәм Габдуллаһ әфәнде Тукаев*».

---

[1] «Ялт-йолт» – Казанда 1910–1918 елларда чыккан журнал. Баш редактор Г. Тукай, Ә. Урманчеев.

[2] http://gabdullatukay.ru/works/articles/articles-1910/felsefi-suzler/

[3] Бигиев М. Рәхмәт илаһийә борһанлары. Нашире: Шәрыкъ китабханәсе. Урски. Оренбургда «Вакыт» матбагасы, 1911. Б. 38.

Әсма-Галия ханымның истәлекләренә караганда, 1912 елда Муса әфәнде Габдулла Тукайны дәвалану максаты белән Санкт-Петербургка кунакка чакыра. Җирле хәлле татарлар да идеяне хуплыйлар һәм ярдәмнәрен вәгъдә итәләр. Бу турыда түбәндәге истәлекләр сакланган: «*...өч-дүрт адәм без Габдулла әфәндене дәгъвәт итмеш идек. Казанда Габдулла әфәнденең гайәт айаныч хәлләре безә мәгълүм иде. Дәгъвәт у мөшкел хәлләрдән Габдулла әфәндене азад итмәк касыд иде. Бән Габдулла әфәнденең квартирасыны, Лотфулла әфәнде һәр көн биш бутылка пивосыны, Галим әфәнде Максудов һәркөнге ашыны-чәене, янә берничә адәм башка хаҗәтләрене тәмамы илә тәэмин кыйлачак идек. Казанда корректорлык шәрәфенә канәгать кыйлуб тормыш Габдулла әфәнде, Петербургда у вакыт интишары фараз кыйлынмыш җәридәдә исмән генә мөхәррирлек хезмәтенә әлбәттә разый улур да Петербургда бәлки калур хыялында идек*»[1].

Муса әфәнде һәм аның дуслары халык шагыйренә кадер-хөрмәт күрсәтергә ниятлиләр, аны башкала белән таныштырырга планлаштыралар, Петербург татар җәмәгатьчелеге белән очрашулар үткәрергә җыеналар. Планнарының берсе Тукайга башкалада чыга башлавы көтелгән «Хәбәр» исемле бер татар гәзитендә формаль рәвештә генә мөхәррир булуны тәкъдим итү була. Моннан тыш, Муса әфәнде Тукайга Финляндияне дә күрсәтергә ниятләгән, андагы табибларга мөрәҗәгать итеп, шунда бер санаториядә дәвалануы да каралган була.

Муса әфәнде, сөйләшенгәнчә, шагыйрьгә кунакханәдә номер әзерләп куйган була. Әмма Петербургка Тукай кисәк кенә, алдан хәбәр-фәлән бирмичә килеп төшә һәм вокзалдан конка яллап Муса әфәнде торган адреска бара: Муса әфәнде болай дип язган: «*Телеграм-фәлән юк иде. истикъбаль кыйламадым. Номер хәзерләп куймыш исәм дә, капуым төбенә килгәч, номерга барайы дия алмадым. Гайәт тар квартирамда үзенә махсус гайәт зур бүлмәдә урын вирдем*»[2]. Шулай итеп, Муса

[1] Рәхимова Асия. Шу мәктүбем сүзләре сезә әманәтдер // Гасырлар авазы / Эхо веков. 1996. № 1/2. Б.200–205.

[2] Рәхимова А., күрс. мәкалә.

әфәнде Тукайны үзенең бүлмәсендә урнаштыра, кадерле кунагына урынны үзенең ятагында җәеп, үзе янәшәдә идәндә йоклый. Үзенең ишле гаиләсен чак кына сыйдырган дүрт бүлмәле фатирда Муса әфәнденең газиз кунакка түр бүлмә хәстәрләп тәкъдим итүе, әлбәттә, күпне белдерә.

Кайбер чыганакларга күрә, Тукайның килүе белән бәйле чыгымнарны үз өсләренә алачакларын ышандырып куйган байлар сүзләрендә тормыйлар. Нәтиҗәдә, шагыйрьне табипларга күрсәтеп, аның сәламәтлеген ныгыту эшләре барып чыкмый. Муса әфәнденең фатирында берничә көн үткәргәннән соң, Сафа Баязитов оештырган банкетка чакыру алган Тукай, үзен кунак иткән хуҗага хәбәр бирмәстән вә хәтта хушлашмастан, фатирдан чыгып китә һәм алга таба үзенә башка берәүләр тарафыннан тәкъдим ителгән бер урынга барып урнаша, ә тагын берничә көннән башкаладан Уфага ук китеп бара. Шулай итеп, Муса әфәнде белән Тукай бу юлы да бер-берсенә якынаеп, дуслашып китә алмыйлар.

Тукайның Муса әфәнде белән күрешеп танышуы, аның өендә кунак булуы, аннан ни сәбәпле әйтми-нитми чыгып китүе турында шул көннәрдә Тукай белән күрешеп аралашкан Кәбир Бәкер[1] исемле татар журналисты үзенең «Тукай Петербургта» исемле китабында язган[2]. Моннан тыш, 1996 елда, «Гасырлар авазы / Эхо веков» журналында Асия ханым Рәхимова каләме белән язылып, әлеге вакыйгаларга өстәмә аңлатмалар биргән «Шу мәктүбем сүзләре сезә әманәтдер…» исемле мәкалә басылып чыга. Биредә шул мәкаләдән Муса әфәнденең шәхсиятенә кагылышлы бер парча китерәсем килә. Бу парча «Вакыт» гәзите мөхәррире Фатих Кәримигә Муса әфәнде тарафыннан бер шикаять рәвешендә язылган хаттан алынды:

«*Мөхтәрәм Фатих әфәнде!*

*…сезең «Вакыт»ыңыз сәхифәләрендә бәнем хакда гайәт уңайсыз сүзләр язылгалады. Тукаев әфәнденең Петербура*

---

[1] Кәбир Бәкер (1885–1944) – язучы, журналист, «Әл-Ислах», «Вакыт», «Нур» гәзитләрендә эшләгән.

[2] Кәбир Бәкер. Тукай Петербургта. Оренбург, 1914.

*кодуме мөнәсәбәте илә язылмыш сүзләр тәмамы илә йаландыр. Бән у йаланларның һәммәсенә сөкүт идәр идем. Ләкин бәнем гаиләмдә мәгыйшәтем хакында, биш баламның вәлидәсе сәййидәм Әсма исменең җәридәләрдә юк-бар хәрифләрнең*[1] *каләме илә интишары хакында аслән тәхәммел идәмәм.*

*Бер мескен, ихтирам касды илә бер адәмне миһман кыйлмак үзрә дәгъвәт идәр. Миһман канәгать итмәз, кидәр. Башка йирдә мискин чакыручыны интикад идәр, сүгәр. Зарар юк. «Әмин миһман»дан у интикад сүзләрене бер хәриф ишетүр дә, интикадны интикам сурәте илә бөтен дөньяйа нәшер идәр. Бурада да зарар юк. Ләкин «Вакыт» кеби бер җәридә «Әмин миһман» истифадә кыйлуб, интикамларыны дәреҗ идәрсә, иштә гөнаһ йалңыз «Вакыт» кеби җәридәдә калур.*

*Сезә, Фатих әфәнде, шу шиддәтле гыйбарәләреми яздым. Бәне бәлки мәгъзүр күрерсез.*

*Бер хәрифнең каләме илә җәридәңездә сәййидәмнең намы язылмыш улмаса иде, бән бәлки сөкүт идәр идем.*

*Сез җәридәңезлә бәнем хәрәмем даирәсенә изенсез һөҗүм кыйлдыңыз. Инде җәридәңездә үз каләмеңезлә, үз имзаңызлә игътизар кеби бер шәй әлбәттә языңыз. Мәкалә иясенең имзасына бән канәгать итмәм. Мәкалә иясенең сүзенә, имзасына бән илтифат итмәм.*

*Җәридә сезең! Һөҗүм сезең! Игътизар әлбәттә сездән улачак...»*[2]

Ни генә булса да, Тукай үзенең хатирәләрендә Муса әфәндегә берничә юл багышлап, болай дип язып калдырган: «[Муса әфәнденең] *фатиры дүрт-биш бүлмәле, шәһәренә күрә якты да. Муса әфәнде рафикасы вә бала-чагасы белән шунда торалар икән. Мин түр бүлмәгә урнаштым... Муса әфәнденең эш бүлмәсендә. Бүлмә әнвагъ гарәби*[3] *китаплар белән тулы. Язу өстәле бер көн, икенче көн, кичә, аннан элек, әле генә*

---

[1] юк-бар хәрифләр – ягъни «Вакыт» гәзитенә мәзкүр мәкаләне язган Кәбир Бәкер үзе күздә тотыла.

[2] Рәхимова А., күрс. мәкалә.

[3] Әнвагъ гарәби китаплар – гарәп телендә язылган төрле китаплар.

*язып ташланган материалларга күмелгән. Муса әфәндenең иртәнге чәе дә, көндезге ашы да, кичкесе дә язу өстәлендә эш арасында, между прочим гына ашалып эчелә… Аңар көн җитми, төн җитми. Ул таң атарда мәзкүр урыннардан кайта, тагын яза, тагы йөгерә. Между прочим гына идәндә йөргән берсеннән-берсе… кечкенә балаларын сөя, җуатып ала*»[1].

Халык шагыйренең вафаты да Муса әфәндене битараф калдырмый. Тукай вафат булгач та, 1913 елның 27 апрелендә үк «Вакыт» гәзитендә аның «Габдулла әфәнде Тукаев» исемле тәһзиясе (некролог) басыла. Шуннан берничә җөмлә: «*Хәяте илә һәммәбезгә, хосусан, яшьләремезгә, мәктәп балаларына җан бирә килмеш иң мөхтәрәм шагыйремез Габдулла әфәнде хәзрәтләре, вафаты илә дә, милләтебездә бар хәят әсәрләрен*[2] *дә күрсәтеп китте… Милли шагыйремез Габдулла әфәнде Тукаев җәнабләрене гаять гүзәл белерем… Өч-дүрт сәнә элек Габдулла әфәнде хакында бер мәкалә язып «Йолдыз» гәзитәсенә җибәргән идем. Басылмады. Югалмаган булса, ул мәкаләмне «Йолдыз» нәшер итсә дә ярар иде. Яшь шагыйрьгә булган чиксез ихтирамым мәгълүм булыр иде…*».

Гомумән алганда, Муса әфәнденең Габдулла Тукайга булган мөнәсәбәте җәмгыять мәнфәгатьләренә хезмәт итеп файда китерүчеләрне үзенең шәхси кичерешләреннән югары куелуына мисал була ала. Чыннан да, дөньядыр бу – адәм балалары арасында төрле хәлләр була, әмма хакыйкый иман иясе кемгә дә булса үпкәләве, хәтта рәнҗеп хәтере калуы сәбәпле һичкайчан үчекләшмәс, аңа аяк чалмас вә,түбән кичерешләргә бирелеп күңел көзгесен тутыкландырмас. Шул ук вакытта, Муса әфәнденең Тукайга карата кылган гамәлләре вә әйткән сүзләре – югары әдәп галәмәте һәм гүзәл тәрбия үрнәге дия алабыз.

---

[1] Әлеге өземтә Рабит әфәнде Батулланың «Дин галименең сурәтенә кайбер шәрехләр» исемле мәкаләсеннән алынды (Муса Бигиев: мирас һәм хәзерге заман. 2000. Б. 175).

[2] хәят әсәрләре – тере, исән булу билгеләре.

## Коръән тәрҗемәсе

Муса әфәнденең тормышында 1912 ел тагын бер истәлекле вакыйга, дөресрәге – драматик кыйсса белән аерылып тора. Бу елны Муса әфәнде Коръән тәрҗемәсен бастыру мәсьәләсен хәл итәргә алына. Коръән тәрҗемәсе инде 1911 елда ук тәмамланган була, 1912 елның гыйнварында ул, Казанга килеп, биредә эшләп килгән «Өмид» басмаханәсе белән тәрҗемәне бастыру турында килешү кора. Аның буенча, апрель аеның 20-ләрендә Коръән тәрҗемәсе, басмага бирелеп, 400 сәхифәлек китап рәвешендә биш мең данә күләмендә басылырга тиеш була.

Бу вакыйгалардан соң чыккан «***Халык назарына берничә мәсьәлә***»[1] («Халык игътибарына берничә мәсьәлә») исемле китабында Муса әфәнде, башкарып чыккан бу эшенә багышлап, «*Коръән кәрим тәрҗемәсе*» исемле фасылда мондый сүзләр яза: «*Табигатьнең, бәлки дә бөтен галәме вөҗүднең*[2] *тәрҗемәсе булган Коръән кәримне үз телебезгә дөрес һәм гүзәл өслүб белән тәрҗемә итү, әлбәттә, тиеш иде. Коръән кәримне бүгенгә кадәр тәрҗемә итмәү гөнаһ булмаса да, моннан соң тәрҗемә итү һичбер сурәттә гөнаһ була алмый*».

Шул ук әсәрендә Муса әфәнде Коръәнне ни өчен «*галәме вөҗүднең тәрҗемәсе*», дип атавын аңлата, әлеге изге китапның нинди юллар узып пәйгамбәр калебенә иңгән илаһи вәхи хәленнән кәгазьгә, сәхтиян күнгә язылып мосхәф, ягъни китапка әйләнүе турында сөйли, аның һичбер хата вә кимчелексез хәтердә һәм язуда теркәлеп калуы тарихыннан мәгълүматлар китерә һәм, акрынлап, Коръәнне милли телләргә тәрҗемә итүнең ифрат та әһәмиятле эш булуын дәлилли: «*Коръән кәрим Рабб Хакимнән Җәбраил Әмин аркылы Нәби кәримнең, галәйһи-с-саләт вә-с-сәлам, калебенә иңгән иң соңгы сәмави китаптыр. Могъҗизави тезмәләрен телләрдә,*

[1] Муса әфәнде Бигиев. Халык назарына берничә мәсьәлә. Казан: Электро-Типография «Умид», 1912. 94 б.

[2] галәме вөҗүд – Аллаһ тәгалә булдырган, барлыкка (вөҗүдкә) китергән нәрсәләрдән гыйбарәт булган галәм; барлык галәме.

*күңелләрдә, мосхәфләрдә үзгәртүсез мәңге саклау вазифасы белән, мәгънәләрен бөтен кешеләргә бәян итү турындагы килешү белән, Нәби кәрим, галәйһи-с-сәләт вә-с-сәлам, тарафыннан әманәт илаһия буларак Коръән кәрим кимчелексез ислам өммәтенең җаваплылыгына тапшырылды*».

Мөселман өммәтенә йөкләнгән ике вазифа, ягъни Коръәнне үзгәртүсез мәңге саклау, аның мәгънәләрен бөтен кешеләргә бәян итү турында тәфсиллерәк аңлатма биреп Муса әфәнде болай дигән: «*Бу ике вазифадан иң мөһиме – Коръәннең кәрим тезмәсен саклау вазифасы Шаригъ хәкимнең үзе тарафыннан башкарылды. Икенчесе – Коръәннең кәрим тезмәләренең мәгънәләрен бәян итү һәм кешеләргә җиткерү вазифасы,– өммәтнең үз тырышлыгына, ирекле ихтыярына тапшырылып, ачык, гомуми бер бәйге мәйданы кебек булды. Хәятнең, фикернең хәрәкәтләрен табигый хәлләрендә калдыру өчен булса кирәк, икенче вазифа хакында Шаригъ кәрим хосусый чаралар күрмәде, бәлки [Коръән] теленең дәлилләүләренә һәм өммәтнең аңлау-төшенүенә таянды. Шуңа күрә хөрмәтле сәхабәләр гасырында, табигыйн арасында, әһле гыйлем, әһле әдәп арасында байтак мөфәссирләр җитеште. Шуңа күрә [Коръәнне] тәфсир кыйлу хосусларында мәзһәбләр юк иде, тәкълид кыйлу юк иде. Шуңа күрә «баб әт-тәфсир мәсдүд»*[1] *дигән нәрсә булмады, тәфсир капкалары янына сакчы куелмады. Бу киңлек, бу хөррият безнең өчен гаять бөек бер бәрәкәт булды: әгәр берәү нинди дә булса бер айәт кәримәне тәфсир иткәндә риваятьләр тәэсире белән, кәлям ысулы белән, мәзһәб кагыйдәләре белән ул айәт кәримәнең мәгънәләрен үзгәртсә, бозса, башка берәү ул җитешсезлекне уртага куеп тәнкыйть итә алу мөмкинлегенә ия иде*».

Алга таба Муса әфәнде Коръәнне тәрҗемә иткәндә үзе үтәгән кагыйдә һәм принципларны, кулланган чыганакларны һәм тәрҗемә итүнең ысул вә алымнарын барлап чыга, аларның һәммәсенә карата ачыклама яза. Боларны укыган кеше Муса әфәнде ясаган тәрҗемәнең никадәр төпле, ышанычлы һәм иң югары дәрәҗәдә гыйльми булып, диннең тәфсир вә

[1] тәрҗемәсе: «Тәфсир кыйлу капкасы ябык».

тәрҗемәгә караган таләпләренә никадәр туры килгән булуын чамалый ала: «*Әһле гыйлем каләме белән язылган тәфсирләр; Коръән кәримнең үзе; Тәрҗемәдә минем иң нык нигезем телнең дәлиледер; Кыйраәт (укылыш) каршылыклары булганда һәрберен игътибарга алдым; Җөмлә берничә мәгънәләрне ихтимал итеп тә, ул мәгънәләрнең һәрбере күздә тотыла алса, ул мәгънәләрнең һәрберен бәян иттем; Коръән кәримнең могъҗиз тезмәсен ислях кыйлу дәгъваларына бервакытта да җәсарәт итмәдем*[1]*; Кәлям*[2] *ысулларына, яңа һәм борынгы фәлсәфә назарларына айәт кәримәләрнең дәлаләтләрен татбикъ итү*[3] *яманлыкларыннан сакландым; Тәфсир кыйлучыларның күбесе йә риваять тәэсире белән, яки тәфсир теләге белән могъҗизави тезмәнең дәлилләрен бозып, кайчак айәт кәримәләрнең мәгънәләрен үзгәртсәләр дә, мин тәрҗемәдә һичбер айәт кәримәдә тәфсир кыйлу я тәэвил итү юлларына авышмадым; Коръән кәримнең мәгънәләре, тезмәсе кебек үк, ныклап теркәлгәннәр, шуңа күрә аны тәрҗемә итү мөмкин*».

Муса әфәнденең катгый фикеренчә, Коръәнне милли телләргә тәрҗемә итү никадәр катлаулы эш булса да, бу эш, шәригать күзлегеннән караганда, фарыз дәрәҗәсендәге гамәл булып тора: «*Мәгънәләрнең һәм образларның төрлелекләре аркасында, тәрҗемә, кайчак, мөмкин булмый. Монысы дөрес. Ләкин Коръән кәрим сүзләренең, җөмләләренең мәгънәләре Кыяматкәчә сабиттыр*[4]*, алар хыял сурәтләре түгел, бәлки хакыйкатьтер. Шуңа күрә Коръән кәримне тәрҗемә итү катгый сурәттә мөмкиндер, шәригать күзлегеннән бакканда ул, хәтта, фарыздыр. Мең телгә тәрҗемә кыйлынсын, ул сакланыр һаман!*»

Аяныч, әмма Муса әфәнденең Коръән тәрҗемәсен бастырып чыгарып, халыкка аңлаешлы телдә ирештерү өмете

---

[1] ислах дәгъваларына бервакыт җәсарәт итмәдем – дөресләү (төзәтү) дәгъвасына беркайчан да батырчылык итмәдем.

[2] кәлям (гыйльм-е кәлям) – ислам динендә иляһилек фәлсәфәсе белән шөгыльләнгән фикер агымы.

[3] татбикъ итү – яраклаштыру.

[4] сабит – нык, тотрыклы.

тормышка ашмый кала, чөнки моңа каршы кадимче фанатик муллалар дәррәү күтәрелеп чыгалар, Коръәнне тәрҗемә итүнең ярамаган эш булуы, мөфтигә тәрҗемәдә Коръәннең мәгънәләре бозылуы турында хатлар язарга тотыналар, тәрҗемә авторына каршы, нахак донослар язып, пычрак аталар. Коръәнне тәрҗемә итүнең яравы-ярамавы турындагы кызу бәхәсләр милли матбугат сәхифәләренә дә ташып чыгалар, шулай итеп Муса әфәнденең исеме белән бәйле булган чираттагы полемик туфан куба. Нәтиҗәдә, доносчы муллаларның ямьсез кыланышларын үзенә якынрак күргән мөфти хәзрәтләре Мөхәммәдъяр Солтанов[1], ул тәрҗемәнең басылып чыгуына юл куймас өчен, наширларга адресланган махсус циркуляр таратып, бу эшне башкаруны тыя. Ни кыласың, әмма тагын дүрт ел үткәч башланып киткән Бөтендөнья сугышында Русия мөселманнарына госманлы дин кардәшләренә каршы сугышырга фәрман биргән мөфтидән башканы көтү дөрес тә булмас иде. Муса әфәнде исә тәрҗемәсенең чыкмый калуына карата «*Халык назарына берничә мәсьәлә*»дә тирән мәгънәле мондый сүзләр язган: «*Коръән кәримнең тәфсире, тәрҗемәсе бөтен ислам өчен гаять мөһим бер бөек мәсьәлә булса да, көннәрне дә, күңелләрне дә караңгылык баскан сәгатьләрдә аны язу мөмкин түгелдер*».

Муса әфәнде калдырган гыйльми мирасның иң олы җәүһәре булган әлеге тәрҗемә шул ук вакытта аның иң аяныч язмышлы хезмәте булып исәпләнә.

«*Халык назарына берничә мәсьәлә*»дә Коръән тәрҗемәсенә багышланган өлеше эчтәлекнең бер генә фасылын тәшкил итә. Китапта бу мәүзугдан башка мәсьәләләр: автор тарафыннан татар-мөселман җәмәгатьчелеге өчен мөһим табылган нәрсәләргә хас әһәмиятнең мәгънәсе һәм авторның каләме белән халык игътибарына тәкъдим иткән мәсьәләләрнең әһәмияте; ул заман язма татар теле мәсьәләсе; татар әдәбиятының киләчәге; цивилизацион күтәрелеш кичергән Көнбатыш

[1] Мөхәммәдъяр Солтанов (Мөхәммәт-Шәриф углы Мөхәммәдъяр Солтанов; 1837–1915) – мөселман дин эшлеклесе, 1886–1915 елларда Оренбург мөселман диния нәзарәтенең 5 нче мөфтие.

белән чагыштырганда ислам дөньясының түбәнгә тәгәрәве сәбәпләре; иман мәсьәләсе; исламиятнең киләчәге һәм башкалар карала. Кушымтада галимнең милли әдәбиятыбызның киләчәгенә кагылышлы фикерләрен китерәбез[1].

Әлеге китаптан Муса әфәнденең кәлям гыйлеме турында язган фикерләре мондый: «*Галәме исламиятнең әүвәлге гасырларында голүм кәламия исемле бер нәрсә барлыкка килде. Ул вакытта безнең иң бөек фәкыйһләребез шул голүм кәламияне, нидәндер, тыялар иде. Аны тыюлары да иң көчле, иң катгый сурәттә иде. Мин моңа аптырый идем. Голүм кәламия исеме кушылуының сәбәбләре дә миңа, ул вакытта, мәгълүм түгел иде.*

*Бу тыюның сәбәпләрен соңыннан гына аңладым: гамәли файдага ия булмаган буш лафлар, мәгънәсез сүзләр белән эш иткәне өчен бу төркем фәннәргә голүм кәламия, ягъни «сөйләмгә корылган гыйлемнәр» дигән исем кушылган булса кирәк, дидем үземә.*

*Бу голүм кәламия файдасыз, буш, юк-бар мәсьәләләр турында бәхәс корып кешенең игътибарын, аның зиһен куәтен заяга сарыф иттермәү нияте белән тыелгандыр, дигән инануга килдем.*

*Мин моны аңладым аңлавын, ләкин шул голүм кәламияне өйрәнү өчен һәммә барлыгымны, вакыт дигән иң газиз милкемне тәмамы белән әрәм иткәннән соң гына аңладым. Хәзерге вакытта ислам дәүләтләре дә моны аңладылар, ләкин исламиятне дә, көч-гыйззәтне дә, дәүләтне дә, идарә-хакимиятне дә, галәме мәдәниятнең*[2] *юлбашчысы булудан колак*

[1] Карагыз: III Бүлек. 5: «Халык назарына» исемле китаптан.

[2] галәме мәдәният – мәдәният галәме, ягъни үзләренең үсеше нәтиҗәсендә гомуми иҗтимагый кануннарга корылган, халыкны берләштергән уртак мәдәнияткә ия булган, колбиләүчелек, феодаль мөнәсәбәтләр кебек борынгылык калдыкларыннан арынган җәмгыятьләр күздә тотыла булса кирәк. Муса Бигиев әлеге төшенчәне еш кына Көнбатышның алга киткән дәүләтләре мәгънәсендә кулланган. Әмма бу урында галәме мәдәният дигәндә сүз кешелек дөньясының иҗтимагый-мәдәни үсеше һәм тәрәккыяте кайчандыр мөселманнар җитәкчелегендә булганы турында бара.

*какканнан соң гына аңладылар. Гомумән, ислам дәүләтләре голүм кәламиянең чын асылы турындагы бу ачы сабакны гаять олы бәя бәрабәренә үзләштерделәр.*

*Бу кадәр авыр дәрестән соң мин дә бу мәсьәләдә ул бөек фәкыйһләрнең карашларына һәм хөкемнәренә кушылдым. Гомуми сурәттә исламият дип аталган бу киң, тирән, күпкырлы һәм кямил иҗтимагый шәригатьнең хөкеменә күрә голүм кәламия, әлбәттә, хәрамдыр, дидем.*

*Ләкин ул бөек фәкыйһләрнең голүм кәламия турындагы хөкем вә фикерләре белән минем бу мәсьәләне аңлавым арасында бераз аерма бар.*

*Фәкыйһләрнең гадәтендә нәрсәнең дә булса хәрам буларак танылуы, ясаклануы җәзага дучар ителмәү, җәзадан котылу максатына кайтып кала. Әмма минем карашымча, нәрсәнең дә булса ясаклануы аның тискәре нәтиҗәләргә китерәчәгенә кайтып кала. Шулай итеп, хәрам булуның нигезендә, фәкыйһләр уйлавынча, җәзадан курку, җәзадан котылу нияте ятса, минем карашыма күрә, хәрам булуның нигезендә шул хәрам ителгән нәрсәнең начар нәтиҗәләргә китерү куркынычы, яман нәтиҗәләргә килүдән курку ята.*

*Шулай итеп, безгә түбәндәгене аңларга кирәк: фәкыйһләрнең гадәте буенча, аларның уйлары буенча «Бу эш хәрамдер» дигән хөкемнең тел төбендә «Андый эшне эшләүче газапка, җәзага дучар ителәчәк» дигән мәгънә ята. Әмма минем аңлавымча, «Бу эш хәрамдер» дип әйтү: «Андый эшнең зарары бар, бозыклыгы бар», дигән мәгънәгә ия.*

*Фәкыйһләрнең югарыда искә алынган гадәтләре, хөкемнәре, карашлары хата түгел. Алар, әлбәттә, дөрес. Ләкин исламият кебек кямил иҗтимагый шәригатьнең хөкемнәренә нисбәтән минем карашым күпкә тугрырак, күпкә дөресрәк булып чыга. Чөнки начар эш кыйлу аркасында Ахирәттә газаплар биреләчәге, җәзага тартылу һәрникадәр хак булса да, ул биреләчәк газап вә җәзалар иҗтимагый хәят, күмәк яшәеш хөкемнәренә һичбер сурәттә нигез ителә алмый, минемчә.*

*Тәхрим кыйлу гына түгел, теге яки бу нәрсәне яки гамәлне хәрам дип тану гына түгел, бәлки һәрбер дини йөкләмә, һәрбер дини фарыз, һәрбер дини вазифа җәзага дучар ителмәү нигезенә, җәзадан котылу ниятенә корылган. Нинди дә булса дини боерыкны, әмерне, фарызны-фәләнне үтәмәү өчен җәза билгеләү, җәзага тартылуны таләп итү кануны, тыюның нигезендә яткан җәзаланудан курку кануны – иң мөһим, иң зур нигездер. Чөнки иҗтимагый шәригать, бер яктан, бары тик иҗтимагый мәнфәгатьләргә, файдаларга юл ачуга, ә икенче яктан, иҗтимагый бозыклыкларга юл куймау нигезләренә корылырга тиеш.*

*Әгәр дә фикъһыга караган гыйлемнәр барлыкка китерелгәндә, әлеге нигез өстенә урнаштырылган булсалар иде, бүген иң яхшы иҗтимагый шәригать ул – исламият булыр иде, ислам булыр иде. Ләкин безнең фәкыйһләр дини йөкләмәләрнең, дини вазифаларның нигезен салганда газап белән савапны беренче урынга куюлары аркасында, шушы ике нәрсәне генә игътибар үзәгендә тотулары аркасында исламиятне иҗтимагый шәригать булудан тәмам мәхрүм иткәннәр.*

*Гыйлем-е кәлам, үзенең киң таралыш алган һәм танылган мәгънәсе белән гакыйдә турында, иман мәсьәләләре һәм нечкәлекләре турында сүз йөртә торган гыйлем мәгънәсенә ия булса да, минем аңлавымча, кәлам гыйлеме гамәли файдага ия булмаган буш сүзләр турында бәхәс итә торган нәрсәләрнең һәрберсен үз эченә ала. Кәлам кебек буш сафсатага аның белән шөгыльләнүчеләр тарафыннан «гыйлем» я «әдәп» исеме бирелүнең дә хикмәте бар. Моның нигезендә үзләренең файдасыз уйдырмаларын халык арасында таратып, аларны кабул иттерү мәкере ята».*

Бу китап турында «Шура» журналында бирелгән анонста мондый сүзләр бар: «*Китапта бәхәс ителмеш нәрсәләр әдәбиятымыз илә шөгыльләнүчеләр өчен нәкадәр мөһим булса, иҗтимагый галимләремез өчен шул дәрәҗәдә әһәмдер. Шәкертләр вә мугаллимнәр, әдип вә мөхәррирләр, мөәллиф вә мөдәррисләрнең һәрбере тарафыннан укылырга, икътидарлы*

*адәмнәр тарафыннан интикад вә мөхакәмә кыйлынырга лаек бер әсәр булуында шөбһә юк*»[1].

Муса әфәнденең югарыда китерелгән фикерләре һәм кискен нәтиҗәләре бүгенге көндә дә әһәмиятен югалтмаган.

1912 елда Муса әфәнде Коръән кыйраәтләренә багышланган «***Таййибату ән-нәшри фи әл-гашри***»[2] («Коръәннең ун кыйраәтен киң таратуның яхшылыгы») исемле китапка шәрех бастыра. «*Таййибәте-н-нәшр*»не милади 1350–1429 елларда яшәгән Мөхәммәд ибне Мөхаммәд ибне Гали ибне Йосыф әл-Җәзәри исемле галим язган. 1391 елда Мәмлүк солтаны Сәйфетдин Баркук[3] аны баш казый итеп билгели, соңрак Аксак Тимер әл-Җәзәрине фикъһы гыйлемен укыту өчен үзенең башкаласы Сәмәркандка озата. Абруйлы фәкыйһ булудан тыш, әл-Җәзәри хәдисләр белгече һәм кыйраәт остасы буларак танылa. Муса әфәнде китапның башында ук әл-Җәзәрине үз вакытында Коръән хафизлары арасанда иң беренче һәм кыйраәт гыйлемендә тиңдәше булмаган галим дип атаган. Бу борынгы әсәрне бастыру белән дә Муса әфәнденең мөселманнар арасында Коръән гыйлемнәрен үстерү һәм таратуга никадәр әһәмият биргән булуы ачык күренә. Гомеренең азагында, бу китабының никадәр әһәмияткә ия булуын ассызыклап, Муса әфәнде мондый сүзләр язган: «*«Таййибәту ән-нәшри фи әл-гашри» атлы китабым кулымдадыр. Укыйм. Аллаһ (җҗ) хәзрәтләренә бөтен калебем белән хәмеде сәна итәмен. 70 еллык гомеремнең сәмәрәсе ялңыз бу китап булса, хәтта минем өчен бу шәрәф җитәр*»[4].

1912 елда Муса әфәнденең, үзе язган хәбәренә караганда, «***Исламияттә кадер***» («Ислам динендә язмыш») исемле китабы дөнья күрә. Бу китапның басылуы турындагы белдерүне

[1] Халык назарына берничә мәсьәлә // Шура. № 24. 1912.

[2] Муса бин Җаруллаһ Рустуфдуни. Таййибату ән-нәшри фи әлгашри. Казан: «Өмид», 1912. 308 б.

[3] Сәйфетдин Баркук (Сәйфетдин Баркук ибн Әнәс; милади 1339–1399) – Мисыр белән 1382–1389 һәм 1390–1399 елларда идарә иткән мәмлүк солтаны, Бөрҗиләр династиясенә нигез салучы хөкемдар.

[4] Uralgiray. Mektuplar, s. 19.

ул «*Халык назарына берничә мәсьәлә*» исемле китабының тышлыгында урнаштырган.

Муса әфәнденең гыйльме һәйәт белән ныклап кызыксынган булуы турында югарыда әйтелгән иде. Шуңа мисал итеп, аның 1912 елда башкарган бер фәнни-астрономик экспедициясен китереп була. Апрель аеның 4-дә кояш тотыла. Муса әфәнде бу вакыйганы үз күзләре белән күреп, кулында булган җиһазларны файдаланып, тикшеренүләр үткәрә. Ахырда «Шура» журналында отчет сыман мәкалә бастыра. Ул мәкаләне кушымтада китердек[1].

## Төркиядә китапларының тыелуы

1913 елның 25 мартында Госманлы Дәүләт-е Галиясенең шәйхелисламы Мөхәммәт Әсад Әфәнде[2], Муса Бигиевнең «*Кавагыйд фикъһийә*» (1910); «*Рәхмәт илаһийә борһанлары*» (1911), «*Инсанларның гакыйдә илаһийәләренә бер назар*» (1911), «*Озын көнләрдә рузә*» (1911) исемле дүрт китабының Дәүләт-е Галиядә сатылуын ясак кылып, фәрман чыгара. Үзенең фәрманында, Муса Бигиев китапларында көфер фикерләр булып, ул китапларның мөселманнарны адаштырыр өчен язылган булуы турында фәтва игълан иткән була. Шәйхелисламның фәтвасын гамәлгә ашырыр өчен ‚Дәүләт-е Галиянең Эчке эшләр вәзирлегенә (министрлыгына) махсус фәрман юллана. Бу ведомство хезмәткәрләре искә алынган китапларны табылган һәрҗирдә конфискацияләргә тиеш булалар. Әлеге фәрман Эчке эшләр вәзирлегендә каралган арада, Госманлы иленең алдынгы фикерле зыялылары матбугатта шау-шулы ризасызлык туфаны кубаралар. Мәсәлән, Госманлы Дәүләте Галиясендә танылган табиб һәм фәлсәфәче Җәүдәт бәй[3] шундыйларның берсе була. «Мир Ислама» жур-

---

[1] Карагыз: III Бүлек. 6. وَخَسَفَ الْقَمَرُ وَجُمِعَ الشَّمْسُ وَالْقَمَرُ

[2] Мөхәммәт Әсад Әфәнде (1847–1918) – 1913 елның 24 гыйнварыннан 1914 елның 15 мартына кадәр Госманлы шәйхелисламы була.

[3] Җәүдәт бәй (Габдулла Җәүдәт Карлыдаг; 1869–1932) – төрек фәлсәфәче һәм мәгърифәтче; белгечлеге буенча табиб булуыннан

налында Җәүдәт бәйнең протесты турында мондый сүзләр бар: «*категорически запротестовал против запрещения, наложенного шейхуль-исламом на сочинения Бигиева*». Шул ук хәбәрнең дәвамында мондый сүзләр китерелә: «*После сильно нашумевшего во всем мусульманском мире распоряжения шейхуль-ислама о запрещении продажи произведений Муса Бигиева, сочинения этого автора стали продаваться в еще большем количестве и без всяких препятствий со стороны властей. Объявление об их продаже в том или другом книжном магазине встречаются чуть ли не во всех газетах. Кроме того, взгляды Бигиева открыто выражаются и константинопольской печатью, и даже лицами, близко стоящими к правительству*»[1].

Бу кадәр каршылык һәм протестлар турында, әлбәттә, хәбәрдар булып торган Эчке эшләр визарәте, үз мәнфәгатьләреннән чыгып, шәйхелисламның Муса Бигиев китапларын конфискацияләүне таләп иткән фәрманын гамәлгә ашырудан баш тарта. Нәтиҗәдә, 10 апрельдә шәйхелислам ул фәрманын, кире алып, гамәлдән чыгарырга мәҗбүр була.

Бу вакыйгалар Муса әфәндегә ишетелми калмый һәм, әлбәттә, тәэсир итә. Төркиядән килгән хәбәрләрне күзәтеп барган галим госманлы җәмәгатьчелегенең, шәйхелислам фәрманын санга сукмыйча, аңа каршы чыгуы турындагы күңелсез уйларын «Вакыт» гәзитенең 8 июнь санында басылган «*Тәәссеф итмештем, артык аңладым*» («Күңелем кырылган иде, инде аңладым») исемле мәкаләсендә язып чыга. Әлеге мәкаләнең урыс теленә тәрҗемәсе белән кушымтада танышырга мөмкин[2]. Муса Җаруллаһның мирасын өйрәнүче төрек галиме Мәхмәт Гөрмәз бәйнең язуына күрә, бу мәкаләне «Ислам дөньясы» журналы кабатлап бастыра. Нәтиҗәдә жур-

---

тыш, шагыйрь, әдәби тәрҗемәче, яшь төрекләр хәрәкәтенең идеологы. 1908–1918 елларда Төркияне модернизацияләүдә зур роль уйнаган шәхес, Мостафа Кәмал Ататөрекнең шәхсиятенә нык тәэсир иткән кеше.

[1] Салим. Обзор мусульманской жизни // Мир Ислама. Т. 2, вып. 2. 1913. С. 127–128.

[2] Карагыз: III Бүлек. 7: «Я, было, огорчился, но теперь понял».

налның басма бүлеге мөхәррире Госман Вөҗүди бәй, судка тартылып, акчалата штраф белән һәм бер ай төрмәдә тотылу белән җәзалана[1].

Гомумән, Төркиядә Муса әфәнде китапларының тыелуы, шуннан купкан матбугат туфаны һәм бу хәлләргә кагылышлы башка вакыйгалар галимнең мирасына һәм аның эшчәнлегенә бәйле булган мәсьәләләрне өйрәнүчеләр өчен бик яхшы һәм перспективалы фәнни тикшеренү темасы булып тора.

## Гаяз Исхакый белән уртак эшчәнлек

1913 елда Русия империясендә Романовлар династиясенең 300 еллык юбилее зурлап үткәрелә. Шул уңайдан амнистия игълан ителә. Сәяси-иҗтимагый активлыгы аркасында 1909 елдан бирле сөргендә яшәргә мәҗбүр ителгән Гаяз Исхакый[2] азат ителә, әмма аңа Казанда яшәү тыела. 1913 елның 3 апрелендә ул Санкт-Петербургка килеп төшә һәм биредә иҗтимагый эшчәнлеген дәвам итеп, «Ил» исемле гәзиткә нигез сала һәм, баш мөхәррир буларак, аны нәшер итә башлый. Гәзитнең беренче саны 22 октябрьдә басылып чыга. Әлеге гәзит сәхифәләрендә Гаяз әфәнде белән инде күптәннән таныш булган Муса әфәнденең берничә мәкаләсе дөнья күрә. Беренче һәм өченче саннарда аның «*Шәригать исламиягә бәнем назарым*» («Ислам шәригатенә минем карашым») исемле язмасы, икенче-өченче саннарда «*Әүвәлге зәхмәтләрне онытмамак ләземдер*» («Элеккеге тырышлыкларны онытмаска кирәк»); алтынчы санда «*Хәтер дәфтәреннән: Мәктәп мәдрәсәләрә, рухани идарәләрә даъир низамлар хакында*» («Хәтер дәфтәреннән: Мәктәп-мәдрәләргә, Диния нәзарәтләренә кагылышлы системалар турында») һәм «*Коръән бозу хакында оналмаз фәсадның чаралары нәрәдә?*» («Коръәнне бозуга китергән

---

[1] Görmez M. Musa Carullah Bigiyef. Ankara: Türkiye Diyanet Vakfı Yayınları: 1994. S.179.

[2] Гаяз Исхакый (Гыйлаҗетдин углы Мөхәммәт-Гаяз Исхакый; 1878–1954) – әдип, татар реалистик әдәбияты классигы, җәмәгать эшлеклесе; мөхәррир, журналист, татар мөһаҗирлегенең актив әгъзасы һәм сәясәт эшлеклесе.

чиксез бозыклыкны бетерүнең чаралары кайда?») исемле мәкаләләре басылып чыга. Һәр мәкаләдә мөселман җәмәгатьчелеген борчыган актуаль мәсьәләләр кузгатыла. Мәсәлән, «*Шәригать исламиягә бәнем назарым*» исемле күләмле язмасында Муса әфәнде ислам хокукын торгынлыкка дучар иткән күренешләрне, фикъһы гыйлеменең җитешсезлекләрен фаш итә; ислам диненә карата реформаторлык, протестантизмның борынгы шәкеле кебек төшенчәләр куллануның зур хата булуы турында сүз йөртә. Әлеге мәкаләнең урыс теленә тәрҗемәсен кушымтада урнаштырдык[1]. Атаклы рус шәркыятьче галиме В. Бартольд җитәкчелегендә Санкт-Петербургта чыга башлаган яңа «Мир ислама» исемле фәнни журнал сәхифәләрендә дә Муса әфәнденең ислам фикере дөньясында сизелерлек хәрәкәт башлануына тәэсир итүен ассызыклап болай дип язылган: «*Прогрессивно-националистический лагерь мусульманской печати России приветствует появление каждой из книг Бигиева с шумным одобрением. В Бигиеве они видят мусульманского Лютера, которому суждено вывести погибающее мусульманство на путь спасения.*

*Константинопольская печать тоже почти вся отозвалась о взглядах и учении северного богослова ислама с большим одобрением*»[2].

1913 елның август аенда Русия башкаласына Истанбулдан шәригать белгече, хатыйб, юрист, тарихчы галим, публицист, күренекле дәүләт эшлеклесе Мәхмүд Әсад Сәед-Шәһир әфәнде (1856–1918) килеп төшә. Муса әфәнде, әлеге мәртәбәле кунакка юлдаш булып, аны татарлар тормышы, мөселман җәмәгатьчелегенең яшәеше белән якыннан таныштыра. Гомумән, Муса әфәнденең госманлы дәверендә дә, җөмһүрият дәверендә дә Төркиянең шундый олпат затлары белән даими сурәттә танышып-аралашып, хәл-әхвәл белешеп торганын истә тотарга кирәк.

---

[1] Карагыз: III Бүлек. 8: «Мой взгляд на исламский шариат».

[2] Мир ислама. Т. 2, вып. IV. С. 225.

Моннан тыш, 1913 елда Муса әфәнде Истанбулда чыгып килгән «Ислам дөньясы»[1] исемле госманлы журналында тагын берничә мәкаләсен бастыра: «*Иман*», «*Мәккә Мөкәррәмәдә гүзәл бер тәшәббес*[2]» һәм «*Мәдәният дөньясы тәрәкъкый итмеш икән, исламият галәме ни өчен иңде?*» («Көнбатыш тәрәкъкый иткәндә ислам дөньясы нигә артка тәгәрәде?»). Соңгы мәкаләнең урыс теленә тәрҗемәсе кушымтада китерелә[3].

## Русия һәм Төркия матбугатында Муса әфәнденең исеме

Муса әфәнденең иҗаты Госманлы зыялыларының игътибарын җәлеп итеп торган: 1913 елның март аенда «Ислам дөньясы» журналның беренче санында аноним автор тарафыннан язылган «*Ислам галәмендә йени җәрайан*» («Ислам дөньясында яңа агым») исемле бер мәкалә басылып чыга. Мәкаләнең авторы сүзен гасырлар дәвамында йоклаган мөселман милләтенең ниһаять уянуы, һәр тарафта мөселманнарның яңа хәяткә таба барулары, яңа максатлар куюлары һәм ислам шәригатенә яңа караш белән багулары турындагы күзәтүләрдән башлый һәм дин галимнәренең, исламны яклап, аның тәрәкъкый һәм исляхатка каршы булмавын исбат итүләренә игътибар итә. Сүзен ныгытып, ул болай дип яза: «*Бу хосуста Мисыр ислам голямәсеннән мәрхүм шәех Мөхәммәд Габдүһ һәм Касим Әмин*[4] *әфәнделәр күп эшләр кыйлдылар*...». Безнең өчен иң әһәмиятлесе – авторның Русия мөселманнары арасында да башланган яңарыш һәм исляхат хәрәкәтләре турында язуы. Бу хосуста ул ике атаклы

[1] «Ислам дөньясы» – Төркиядә яшәгән татарлар тарафыннан чыгарылган Ислам журналларының берсе. Эшне башлап йөрүче Габдрәшит хәзрәт Ибраһим була.

[2] тәшәббес – нинди дә булса яхшы эшкә керешү, башлам; инициатива.

[3] Карагыз: III бүлек. 9: «Почему Запад когда прогрессировал, мир ислама двигался к упадку?».

[4] Касим Әмин (1865–1908) – мисырлы фәлсәфәче, хокук белгече, юрист, сәясәт һәм җәмәгать эшлеклесе, мисыр милли хәрәкәтенә һәм Каһирә университетына нигез салучыларның берсе, исламда хатын-кыз хокукларын яклап чыккан язучы.

шәхесне атый: берсе рус телендә «Ислам и прогресс» (1898) исемле принципиаль яңа китап язган Гатаулла ахунд Баязитов булса, икенчесе, авторның сузләре белән әйткәндә: «*дин галимнәре арасында иң мөнәввәре [нурлысы], Коръән Газыймны төрекчәгә тәрҗемә иткән Муса әфәнде Бигиев хәзрәтләреләр*».

Шул ук 1913 елда «Ислам дөньясы» журналының июнь, июль, август айларында чыккан саннарында «*Муса Җаруллаһ әфәнденең мәкаләләре мөнәсәбәте белән*» дигән исем астында Мөхәммәт Гыясетдин каләме белән язылган бер һәм Шәех Исмәгыйль каләме белән язылган өч мәкалә басылып чыга. Гомумән алганда, искә алынган мәкаләләрдән аңлашылганча, төрек матбугатчылары һәм журналистлары ул чакта Русиядә яшәгән мөселман голәмәсе арасында Муса әфәндене иң алдынгысы буларак таныганнар һәм олылаганнар.

Муса Бигиевнең иҗатын Русия матбугаты да игътибарга ала. «Мир ислама» журналында исеме түбәндәге контекстта телгә алынган: «*Самый важный и самый благой признак нашего века, это появление среди улемов людей мыслящих и ищущих света… Их цель – спасти мусульманский мир от невежества… Джемал ад-Дин аль-Афгани… Мухаммад Абдо, Амир аль-Хинди, Ходжа Тахсин, Исмаил Хакки, Шахабатдин Марджани, Алимжан Баруди, Зияэтдин Абдур-Решид, Муса эфенди Бекиев, каждый по мере своих способностей могут считаться теми «современными улемами»*»[5].

Шул ук журнал 1909–1910 елларда Муса әфәнденең «Шура» сәхифәләрендә басылып чыккан диннәр тарихы дәресләрендә яңгыраткан фикерләренә карата рус шәркыятьче галимнәренең түбәндәге фикерләрен китерә: «*Горькое сознание мусульманского бессилия… породило убеждение в необходимости… смело обличать недостатки мусульманского богословия и горячо протестовать против тех уз, которыми опутана мусульманская жизнь, благодаря формализму, доктринерству и консерватизму официальных толковате-*

[5] Два течения. Современные улемы // Мир Ислама. Т. 2, вып. 1. СПб, 1913. С. 41–42.

*лей-улемов… Сочинения Муса Бигиева стали вдруг и без явной причины предметом особого внимания. Идеи татарского философа все больше и больше начали распространяться среди константинопольских мусульман. Его смелая критика старых толкований, к которым до сих пор относились с таким благоговением, начали нравиться очень многим»*[1].

Ниһаять, Русия мөселманнары тормышын күзәтеп торган әлеге фәнни журналның сәхифәләрендә Муса әфәндене хуплап телгә алган төрек зыялысы Шәмсетдин бәйнең «Төрек йорты»нда басылган сүзләре урын ала: «*Наконец-то появился ученый в России, который своими сочинениями приобрел себе всеобщую известность. Это – Муса Бигиев. Нет сомнения, что он является истинным новатором в исламе*»[2].

Алдагы саннарының берсендә «Мир ислама» Муса әфәнде язган мәкаләләрнең берсен тулысынча тәрҗемә итеп бастыра[3]. Бу да татар галименең никадәр тәэсирле, тирән эчтәлекле әсәрләр иҗат итүенең бер күрсәткече булып тора.

Муса әфәнде һәм аның эшчәнлеге, әлбәттә, жандармериянең дә игътибарын җәлеп итә. 1913 елның ноябрь аенда әлеге ведомствоның Казандагы хезмәткәрләренең берсе «Йолдыз» гәзите редакторы Әхмәт-Һади Максудиның өендә җыелган зыялылар арасындагы бер сохбәт барышында сүзнең Муса Бигиевкә дә кагылып алуы турында язган. Очрашуда катнашучылар «Шәригать исламияйә бәнем назарым» исемле мәкалә турында фикер алышканда, Бигиевнең Көнбатыш Аурупада Реформация башлаган Мартин Лютер[4] ролен уйнарга омтылуы турында сүз әйтелә. Очрашуда кат-

---

[1] Обзор мусульманской жизни // Мир Ислама. Т. 2, вып. 2. СПб, 1913. С. 126

[2] Мир ислама. Т. 2, вып. IV. 1913. С. 226.

[3] Муса Бигиев. Будущее мусульманства. (Перевод) // Мир ислама. Т. 2, вып. V. 1913.

[4] Мартин Лютер (1483–1546) – алман дин галиме, дин һәм җәмгать эшлеклесе, монах, католик динен тамырыннан үзгәрткән Реформация хәрәкәтенең идеологы һәм башлап йөрүчесе, Библияне алман теленә тәрҗемә иткән кеше, алман әдәби теленә нигез салучы.

нашкан Садри Максуди[1] мөселман дөньясына Лютер кебек кеше кирәк булса да, Бигиевнең андый реформатор була алмавын ассызыклый, чөнки ул үзе Лютер булырга теләсә дә, тарихи вакыйгаларның агышы аны алга чыгармавы турында фикер йөртә. Донос язган шымчы Садри Максудиның бу сүзләреннән аның үзенең Лютер булырга теләве сизелеп торуы турында да язган.

Әлеге документтан аңлашылганча, югары катлам татар зыялылары арасында жандармериянең яшерен агентлары да булган. Аннары, Көнбатыш Аурупа илләрендә XV–XVI йөзләрдә башланган Реформациянең исламга да кирәк булуына инанган бер төркем зыялыларның дини яңарышның, гомумән, ни асылын, ни максатын аңлап бетермәүләре ярылып ята. Муса әфәнде исә, Лютерны олыласа да, беркайчан да исламга реформация кирәклеге турында сүз әйтмәгән. Моны раслап ике мисал китерергә мөмкин. Аларның беренчесе «Халык назарына берничә мәсьәлә» исемле китапта бәян ителгән: «*Бөек реформатор Мартин Лютерның*[2] *ул тарихи көннәре – Дәүләт госмания солтаннарының иң бөеге булган солтан Сөләйман Кануни*[3] *көннәренә туры килгән иде. Ягъни, ул вакытта нәсаранrealият дәүләтләре исламият дәүләтенә нисбәтән зәгыйфь иделәр. Ләкин Мартин Лютер кебек бөек*

[1] Садри Максуди (Низаметдин углы Садретдин Максудов Арсал; 1878–1957) – күренекле җәмәгать һәм дәүләт эшлеклесе, юрист галим, тарихчы, педагог, II һәм III Дәүләт думасында Казан губернасы депутаты.

[2] Мартин Лютер (1483–1546) – Алманиядәге дини Реформация хәрәкәтенең идеологы һәм җитәкчесе, әлеге хәрәкәтне 1517 елда Виттенберг шәһәрендә католик мәзһәбнең төп нигезләрен инкяр иткән 95 маддәлек дәгъвасын игълан итүдән башлаган дин галиме.

[3] Сөләйман Кануни (Сөләйман I; госм.: Süleymân-ı evvel, төр.: Birinci Süleyman, Kanuni Sultan Süleyman, 1494–1566) – Госманлы дәүләтенең унынчы солтаны. 1520 елның 22 сентябреннән башлап хакимлек итә; 1538 елдан хәлифә була. Сөләйман Кануни Госман ыруыннан чыккан солтаннар арасында иң бөек солтан булып санала. Ул идарә иткән дәвердә Госманлы дәүләте үсешенең һәм куәтенең иң югары ноктасына ирешә.

*яңартучы-мөҗәддиднең бәрәкәте белән нәсаранийат галәме тәрәккыять юлына йөз тотты; әмма Ибне Кәмал*[1]*, Әбу әс-Сөгуд*[2] *кебек кәламчы шәйхелисламнарның бәрәкәте белән исламият галәме түбәнлек инешләренә төшерелде. Ягъни: акылның азатлыгы бәрәкәтендә мәдәният дөньясы тәракъкый итте; акылның тоткынлыгы шомлыгында исламият галәме түбәнгә тәгәрәде*».

Икенче мисал, ягъни Муса әфәнденең ислам диненә реформация, лютерлык кебек нәрсәләрнең һич тә кирәк булмавы турындагы фикерләре инде искә алынган «*Шәригать исламиягә бәнем назарым*»да бәян ителә. Гаҗәп, бу мәкаләсендә Муса әфәнде сүзен ачык әйтүенә карамастан, зыялы замандашлары, хәтта якын дуслары ни өчен аны һаман ислам Лютеры булырга тырышуда гаепләгәннәр икән? Бик сәер хәл…

Әмма башкача уйлаган кешеләр, әлбәттә, булмаган түгел. Мәсәлән, Муса әфәндене үзенең остазы итеп таныган Галимҗан әл-Идриси болай язган: «*Муса Җаруллаһ әфәндегә кайберәүләр Исламиятнең Лютеры дисәләр дә, Муса әфәнде үзе бу бәяләүгә даимән каршылыгын белдерә иде. Муса әфәнде Исламиятнең Лютеры булмавы белән бергә, һич шөбһәсез, хәзрәти Пәйгамбәрнең «Аллаһ бу өммәткә һәр йөз елның башында диннәрен яңартачак берене җибәрер» дип хәбәр биргән мөҗәддидләрдән берсе һәм иң бөегедер. <...> Муса әфәнде исламиятнең хакыйкатьләрен тиешле сурәттә белгән, тиңдәше булмаган бер мәдәни һәм әхлякый кыюлыкка ия булган һиҗри 14 нче гасырның ислам мөҗәддиде булган бер төректер*»[3].

---

[1] Ибне Кәмал (Шәмсетдин Әхмәд Чәләби / Ибне Кәмал Пашазадә, 1469–1534) – 1526–1534 елларда Госманлы Дәүләт-е Галиясенең шәйхелисламы.

[2] Әбу әс-Сөгуд (Әбу әс-Сөгуд-әфәнде, 1490–1574) – 1545–1574 елларда Госманлы Дәүләт-е Галиясенең шәйхелисламы.

[3] Идриси Г. Тәрҗемәи хәл: Муса әфәнде Биги (өзекнең чыганагы: Kadimle Cedit Arasında Musa Cârullah. Hayatı/Eserleri/Fikirleri. Ankara: Dergâh Yayımları: 2005. б. 96).

1913 елда Госманлы Дәүләт-е Галиясендә Мөхәммәт Һашим Наһит[1] каләме белән язылган «*Төркия өчен нәҗат вә игътиляъ юллары*» («Төркия өчен коткарылу һәм күтәрелү юллары») исемле китабы басылып чыга. Һашим Наһит (1880–1962) – танылган хокук белгече, Төркиядә төрле дәүләт оешмаларында җаваплы урыннарда эшләгән. Искә алынган китабын язган чакта Истанбул Милек идарәсенең мөдире буларак дәүләт хезмәтендә була. Үзенең китабында ул, Муса әфәнденең әсәрләреннән күләмле өземтәләр китереп, анда бәян ителгән фикерләрне алкышлап каршылый, аларга иң югары бәя бирә[2]. Һашим Наһит, әлбәттә, бу мөнәсәбәтендә ялгыз булмаган. Аны без һич тә икеләнмичә ул замандагы Төркиядә яшәгән мәгърифәтле, прогрессив һәм эшлекле иҗтимагый катламның бер вәкиле буларак, шул катламда хөкем сөргән рухи һәм интеллектуаль мохитне, ул катламның омтылышларын һәм өметләрен массакүләм мәгълүмат мәйданнарында чагылдыручыларның берсе буларак кабул итә алабыз. Һашим Наһитның китабы аркылы ул чактагы Төркиядәге алдынгы карашлы зыялыларның Муса әфәнденең ислам динендәге проблемаларны яктыртуы белән дә, аларны хәл итү өчен тәкъдим иткән чаралары белән дә тулысынча риза-канәгать булулары чагылган. Димәк, төрек зыялылары татар галименең ислам диненә караган идеяләрен Госманлы Дәүләте кадәр дәүләттә дини вазгыятьне яхшыга таба үзгәртергә яраклы дип тапканнар.

---

[1] 1934 елдан соң Һашим Наһит Эрбиль буларак мәгълүм.

[2] Һашим Наһитның китабы кулыбызда юк, әмма аның бу китабы турында да, анда китерелгән мәгълүмат турында да Госманлы дәүләтендә ике мәртәбә (1919 һәм 1920 елларда) шәйхелислам булган Мостафа әфәнде Сабри (1869–1954) китабыннан укып белдек. (Карагыз: Мостафа Сабри. Дини мөҗәддидләр, йахут «Төркия өчен нәҗат вә игътиляъ юллары»нда бер раһбәр. Шаһзадә башы: Әүкаф матбагасы. 1338–1340. Б. 11–12, 43–44.

## «Әманәт» нәшрияты һәм гыйльми эшчәнлек

1914 елның февраль аенда Санкт-Петербургта «Әманәт» дип аталган татар нәшрияты ачылышына хөкүмәт тарафыннан рөхсәт бирелә. Бу эшне 1913 елда башкалага килеп урнашкан Гаяз әфәнде Исхакый башлый. Тынгы белмәс милләтпәрвәр зат нәшриятка нигез салуга бәйле эшләрне Муса әфәнде һәм башкалада яшәгән башка күренекле татар зыялылары белән бергәләшеп башкара. Нәшрият үзенең эшен атаклы сәүдәгәр, җәмәгать эшлеклесе Мөхәммәт-Галим Максутов[1] тарафыннан бирелгән фатирда башлый. Муса әфәнде «Вакыт» гәзитенең февраль аенда чыккан саннарының берсендә милләттәшләренә мөрәҗәгать бастыра. Мөрәҗәгатьтә ул яңа ачылган нәшриятның фәлсәфәсе һәм максатлары турында баш сүз әйтеп, эш планнары белән таныштыра. Аерым игътибарны фикъһыга караган бер әсәрнең бастырыла башлавына юнәлтә. Бу китапта борынгы һәм соңгы дәвер галимнәренең мирас бүлүгә карашлары, борынгы китапларда бөтенләй каралмаган нәселләрнең килеп чыгышы, мирасның өлешләре, васыять һәм әлеге нәрсәгә дүрт мәзһәбнең карашы, вәлиләр, ягъни ятимнәрнең һәм үз акылында булмаганнарның малын багарга куелган кешеләр, вакыфлар, бүләк ителгән һәм әҗәт итеп бирелгән мал, варислар арасында җир бүлү һәм шәригать даирәсенә караган башка җитди мәсьәләләр бәян ителәчәге турында хәбәр ителә. Муса әфәнденең мөрәҗәгате исә укучыларның, кызыксынган кешеләрнең әлеге мәүзуглар буенча карашларын аңа җиткерүләрен үтенүдән гыйбарәт. Моннан тыш, нәшрияттә эшләнгән беренче башлам булып,

---

[1] М-А. Максутов (Мөхәммәт-Галим әфәнде Максутов, 1930 елда вафат) – империя башкаласы Санкт-Петербургта олы хөрмәт казанган сәүдәгәр, эшмәкәр, матбугатчы, күренекле җәмәгать эшлеклесе. Чыгышы белән Касыйм ханлыгы варислары булган Касыйм татарларыннан, туган урыны – Рязань губернасының Касыйм өязе Татарбай авылы. 1914 елда типография сатып ала һәм аңа «Әманәт» исемен бирә. Ике ел дәвамында (1914–1916 елларда) Максутов басмаханәсендә гомуми тиражы 84113 данәгә җиткән 28 исемле китап, шул исәптән Муса әфәнде Бигиевнең берничә әсәре басылып чыга.

«Ил» исемле татар гәзите чыгару тора. Гәзитнең беренче саны 1913 елның октябрь аенда дөнья күрә, 1914 елда редакция Мәскәүгә күчә һәм шунда ул 1918 елның март аена кадәр чыгуын дәвам итә. Бу гәзиттә Муса әфәнде белән бергә Йосыф Акчура[1], Гаяз Исхакый, Зәки Вәлиди, Сәгыйт Рәмиев кебек башка күренекле татар зыялылары һәм җәмәгать эшлеклеләренең мәкаләләре басылып тора.

Шул ук 1914 елның июнь башларында, Муса әфәнде белән Ризаэтдин хәзрәт Фәхретдин бергәләп, Хәсән әфәнде Акчуринның[2] чакыруы белән Гурьев каласына кунакка баралар. Риза хәзрәт бу сәфәре турында: «*Бу вакытта гомерләр эш эшләп түгел, бәлки истирахәт кыйлып вә мөсамәрә[3] берлә үтте*»,– дип, кунакта көннәрен һәм төннәрен рәхәтлектә үткәргәнен язып калдырган. Аның хатирәләренә күрә: «*Русия мөселманнары арасында иң бай көтепханәләр дамелла Галимҗан хәзрәт [Баруди], Дибирдиевлар, Хәсән Акчурин, Әхмәт Исхакый, Муса әфәнде [Бигиев] көтепханәләредер... Мәгәр дә Хәсән хәзрәт әфәнде көтепханәсе тәртипсез иде, Муса әфәнде берлә без дәхи дә тәртипсезләндереп киттек*». Татар зыялыларының көнкүрешләре, аралашу даирәләре хакындагы бу хәбәр парчаларыннан безнең өчен иң кызыклысы могътәбәр Риза хәзрәтнең Муса әфәнде китапханәсенә биргән бәяседер. Илебез, милләтебез, телебез язмышы кебек үк, бу китапханәнең дә язмышы аяныч: тормышның мәрхәмәтсез давыллары аны тузгыта: бер өлеше бүгенге көндә Санкт-Петербургтагы архивларның берсендә, бер өлеше Төркия Милли китапханәсендә, ә аерым китаплары безгә мәгълүм һәм гайре мәгълүм кешеләрнең шәхси китапханәләрендә саклана. Муса әфәнденең үз вакытында иң бай саналган китапханәсенә

---

[1] Йосыф Акчура (Хәсән углы Йосыф Акчурин; 1876–1935) – күренекле сәясәт, җәмәгать һәм дәүләт эшлеклесе язучы, тарихчы.

[2] Хәсән Акчурин (Тимербулат углы Хәсән Акчурин; 1866–1916) – чыгышы белән Сембер губернасыннан; морзалар нәселе вәкиле; үз вакытында эшлекле сәүдәгәр, фабрикант, нумизмат, китап сөюче, иганәче (меценат) буларак танылган.

[3] мөсамәрә – кичке әңгәмә, дус-ишләр белән сөйләшеп утыру.

һәм шәхси архивына кергән китапларны, кульъязмалар, хатлар, көндәлекләр кебек язма документларны барлап, аларның исемлеген төзү, иншаллаһ, бездән соңгы тикшеренүчеләр тарафыннан башкарылыр.

Гурьевтан Муса әфәнде, Русия мөселманнарының сәяси тормышын бераз җанландырып җибәрәчәк вакыйгада катнашыр өчен, башкалага юл тота. Сүз 1914 елның 15–25 июнендә Санкт-Петербургта үткәрелгән Русия мөселманнарының IV нче корылтае турында бара. Бу чара Рус империясе дәверендә үткәрелгән мөселман корылтайларының соңгысы була. Корылтай эшендә катнашкан кырыклап делегат арасында, башкала мөселманнарының вәкиле буларак, Муса әфәнде дә бар. Делегатлар Бигиевне корылтайның сәркятибе итеп сайлап куялар. Бу чарада күбесенчә Русия мөселманнарының дини эшләре белән идарә итү, шул исәптән, дини нәзарәтләрнең активлыгына кагылган мәсьәләләр карала. Муса әфәнде корылтай эшчәнлегендә делегат буларак та катнаша: мәртәбәле җыен минбәреннән ул һәрнәрсәдән элек дини мәсьәләләрнең хәл ителергә тиешлеген дәгъвалый. Аның уйлавынча, хәл ителергә тиешле башка мәсьәләләр дини вазгыять яхшыга таба үзгәртелгән очракта гына уңай чишелеш таба ала. Моннан тыш, Муса әфәнде милләттә тамырланган кайбер тискәре сыйфатларга да игътибар итеп, халыкка бәрәкәтле хезмәт күрсәткән шәхесләрнең кадерен белмәү, аларны санга сукмау кебек чирләрне фаш итә. Әлеге корылтайдан калган тәэсирләр Муса әфәндене түбәндәге сүзләре язып чыгарга этәрә: «*Бездә, шөбһә юк, хәрәкәт башланды. Бу гомуми иҗтимагый хәрәкәттә байтак адәмнәрнең куәтләре катнашса да, арада биш-ун адәмнең куәтләре күбрәк иде, хезмәтләре дә зур иде, бәрәкәтле булды. Милләт, шөбһә юк, файдаланды, ләкин без ул хезмәтләрне игътибарга алмадык, инкяр иттек. Хезмәтләрен кадерләү булмавы [аркасында] мәйдан буш калды. Гомуми хәрәкәтләребезне басып алган торгынлык һәм сүлпәнлек сәбәбләренең бере, әлбәттә, будыр.*

*Гомуми хәрәкәтләребезнең тарихы миңа мәгълүмдер; матбугатыбызны да беләм; зур җыеннарыбызның һәрбе-*

*рендә катнаштым, раһбәрләребезнең, хадимнәремезнең һәрберен беләм. Безгә кирәкле булган нәрсәләрнең һәрбере, диик, бездә бар, ләкин кешене ихтирам итү, хезмәтләрен кадерләү, үзе дошман аркадашның хак фикерен, яхшы сүзен кабул итү кебек иң кирәкле сыйфатлар, гафу кыйлыгыз, бездә гаять аздыр.*

*Рәшид әфәндене*[1] *арадан качырдык; Галимәрдан бәк*[2] *кадеранә хезмәтләренә лаеклы игътибар казана алмады; Мөхәммәд ага Шаһтахтински*[3] *бүген Петроград урамнарында яланаяк калды; Әхмәд бәк Агаев*[4] *җәнаблары качты. Бүген хезмәт мәйданнарында исемнәре бар адәмнәрнең бер-берсенә ихтирамы калмады, яки юк иде, юктыр. Урынлы булса иде, биредә мин Садри әфәнде кебек адәмнәрнең исемнәрен, хезмәтләрен мисал буларак искә алыр идем. Нәшер ителүенә ирешә алсам, «Ислахат әсасләре» исемле әсәремне дә соңгы ун ел эчендә хезмәт иткән адәмнәрнең хезмәтләрен кадерләү юлында, иншаллаһ, турылыклы әманәтле каләм белән хакыйкатьне язармын. (...) Бүген арада ихтирам бетте; беребезнең башкабызга таянуы, ышануы калмады; нәфрәтләшү гомумиләште; гаепләү күзе белән карашу, бер-беребездән курку гомуми бер бәла булды»*[5].

---

[1] Рәшит әфәнде – Габдерәшит Ибраһимов.

[2] Галимәрдан бәк – Галимәрдан Тупчибашев.

[3] Мөхәммәд Шаһтахтински (Мөхәммәд ага Мухаммед-Таги-Солтан оглы Шахтахтинский; 1846–1931) – күренекле азәрбайҗан мәгърифәтчесе, публицист, шәркыятьче, тел галиме, педагог, җәмәгать эшлеклесе. Халыкара фонетик җәмгыять әгъзасы (1899), Халыкара Азия җәмгыяте әгъзасы (1900), Император Рус География җәмгыятенең Кавказ бүлеге әгъзасы (1903). Фәнни һәм әдәби әсәрләрен азәрбайҗан, рус, алман, франк, инглиз, гарәп, госманлы һәм фарсы телләрендә язган.

[4] Әхмәд Агаев (Әхмәд бәк Агаоглу; 1869–1939 года) – азәрбайҗан һәм төрек җәмәгать эшлеклесе, сәясәтче, публицист, «Хәят» гәзите редакторы, журналист, педагог, язучы һәм төркиятче галим.

[5] Муса Җаруллаһ. Остаз мөхтәрәм Риза әфәнде хәзрәтләренең «Дини, иҗтимагый мәсьәләләр»енә интикад мөнәсәбәтейлә (берничә) мөляхазә. СПБ.: Типография М-А. Максутова. Б. 20–21.

Чыннан да, IV мөселман корылтаендагы мохит аннан алда булып узган корылтайларның гомуми җанлану, күңел күтәренкелеге, ташып торган өметләр һәм зур ниятләр мохитенә һич тә охшамаган. Муса әфәнденең югарыда китерелгән сүзләрендә әнә шул төшенкелек тә чагылыш тапкан.

Корылтай эшенең нәтиҗәләре буенча Муса әфәнде тарафыннан урыс телендә әзерләнгән «Проект положения об управлении духовными делами мусульман Российский империи» исемле җыентык басыла. Корылтайның эше дәвамында барлыкка килгән документларны туплап, татар телендә бастыру да янә Муса әфәнденең җилкәсенә ята. Ул бу эшне башкарып чыга һәм 1915 елда «***Исляхат әсасләре***» исемле китап бастыра. Бу әсәр турында сүзебез алда булыр.

Муса әфәнденең 1914 елда басылып чыккан «***Маъидә***», «***Дәүләт думасында мәет якмак мәсьәләсе***», «***Бөек мәүзугларда уфак фикерләр***» һәм инде телгә алынган «***Мөляхәза***» исемле дүрт китабын атый алабыз. Китапларның һәммәсе дә Петроградта, югарыда искә алынган Мөхәммәт-Галим Максутовның басмаханәсендә чыга.

Авторның язуына күрә, «***Маъидә***»[1] («Аш табыны») 1913 елның 26 ноябрендә Дәүләт Думасына корбан чалу турындагы закон ляихәсе (проекты) кертелүенә һәм Русия мөселманнарының 1914 елдагы сәяси-иҗтимагый хәрәкәтләренә нисбәтән язылган. Моннан тыш, бу хезмәтендә Муса әфәнде мөселман ризыгына һәм корбан чалуга караган кайбер хәл ителми калган мәсьәләләргә дә ачыклык кертергә ниятләгән. Бу турыдагы мәгълүмат китапның гонван (титул) битендә бирелә. Китапның күләме әлләни зур түгел, аның тексты аерым бүлекләргә бүленмәгән. Ләкин алай булса да, эчтәлегенең аерым-аерым темалардан торган катгый структур бүленешкә һәм мантыйкый тәртипкә салынган булуы бик ачык күренә.

«***Маъидә***» Муса әфәнденең фикъһы гыйлемендә, ягъни ислам хокукы өлкәсендә куйган хезмәтенең, дөресрәк әйткәндә – иҗтиһадының күркәм мисалы булып тора. Галимнең бу әсәре белән танышып чыкканнан соң, әлеге бик гади

[1] Муса Җаруллаһ. Маъидә. СПб.: Тип. М-А. Максутова. 34 б.

булып күренгән хәлал һәм хәрам ашамлыклар мәсьәләсендә борынгы галимнәрнең иҗтиһады нәтиҗәсендә чыгарылган фәтваларның шактый сай, каршылыклы һәм примитив булуы фаш ителә. Ә бит нәкъ киресе булырга тиеш иде кебек, чөнки Коръәндә һәм Сөннәттә мөселман ризыгына караган хөкемнәр бик тә аңлаешлы һәм төгәл бәян ителгәннәр. Шундый гадилекне һәм ачыклыкны санга сукмыйча яки күрмәмешкә сабышып, буш җирдә һич юктан җитди шәргый мәсьәләләр булдырып, аннары ул мәсьәләләрне хәл итәр өчен тау-тау китаплар язган, берсе белән берсе бәхәсләшә-бәхәсләшә гади мөселманнарның яшәешләрен катлауландырган дин галимнәренең акыл ягыннан сәламәтлекләренә карата шик туа.

Муса әфәнде борынгы фәкыйһлар уйлап чыгарган шәригать хөкемнәреннән ялган изгелек пәрдәләрен алып ата. Авторның төрле мәзһәбләрдә бер үк мәсьәләләргә карата кабул ителгән шәргый хөкемнәрне бәян итүе һәм, шул ук вакытта, аларның берсенә-берсе капма-каршы килүләрен фаш итүе дә уйландыра һәм катгый нәтиҗәләргә китерә. Муса әфәнде үз карашларын мәҗбүри кабул ителергә тиешле бер нәрсә буларак алга сөрми, ул укучысын мөстәкыйль нәтиҗәләр чыгаруга этәрә. Бу нисбәттән, елкы итенең хәлаллеге турындагы фикерләре Русиядә яши торган мөселманнар өчен әле бүген дә бик актуаль булып тора.

Мәзкүр китапта Муса әфәнденең кеше ашаган ризыкның аның сәламәтлегенә, диненә, холкына тәэсир итүе турындагы фикерләре аерым игътибарга лаек. Әлеге тема китапның аерым бер өлешендә ачыклана һәм бәян дәвамында тагын ике-өч мәртәбә искә алына. Мәсәлән, ул болай дип яза: «*...һәр начар нәрсә, һәр хәбис нәрсә хәрамдер. Андыйларны ясаклау, хәрам кыйлу – кешене аның я бәдәненә, я диненә зыян китерә алган нәрсәләрдән химая кыйлу, саклау чарасы буларак кабул ителгән*».

Бу фикер безнең заманда да көнүзәк мәсьәлә булып кала. Аерым алганда, аның «дингә яман тәэсир» дигән сүзләре «автор нәрсәне күздә тотты икән?» дигән сорау тудыра. Хәрам кылынган ризыкның кеше рухи халәтенә зыян китерүенә игъ-

тибар иттерергә теләгәнме ул, әллә башка бер тәэсирне күздә тотканмы? Җавап, әлбәттә, китапның үзендә бирелә. Галимнең фикеренчә, хәрам булган ризыкны ашау кешенең рухиятенә түгел, аның бәдәненең пакьлегенә тәэсир итә. Ягъни, хәрам ризык ашау тәһарәтне боза, шуңа күрә андый кешенең намазы да кабул булмый, дигән нәтиҗәгә киленә.

Муса Бигиев борынгы китапларда шәргый мәсьәләләрдә чамадан тыш вакчыллану һәм андагы фәтваләрдә мәдәни мохит үзенчәлекләренең исәпкә алынмавын да тәнкыйтеннән читтә калдырмаган. Галимнең фикеренчә, шәригатьчеләрнең шундый хөкемнәре нигезендә гарәп булмаган мөселман халыкларының ашау-эчү үзенчәлекләре һәм гадәтләре Коръәндәге ачык күрсәтмәләреннән чыгып түгел, гарәпләрнең азык-төлеккә кагылышлы зәвыкларыннан чыгып формалашкан. Корәннең рухын тоймау сәбәпле, үзләренең карарларының нигезе итеп, Изге китапка кагылышлы булмаган нәрсәләрне алган фәкыйһларга карата тәнкыйте аеруча кызыклы. Мәсәлән, ул болай дип язган:

«*Ягъни, гарәп зәвыгы теге яки бу ризыкны хуш күрсә, ул ашамлык башка милләт мөселманнары өчен дә яхшы дип санала; әгәр дә гарәпләрнең табигате ул ашамлыктан нәфрәт итсә, ул нәрсә башкалар өчен начар дип санала. Фәкыйһләрнең яхшы ризык белән начар ризыкка биргән билгеләмәләре әнә шундый мөнәсәбәткә кайтып кала. Дөрес, таййибат [яхшы нәрсәләр], хәбаис [начар нәрсәләр] сүзләре – гарәп сүзләре. Гарәп сүзләренең мәгънәләре гарәпләрнең гореф-гадәте белән, гарәпләрнең аңлаулары белән тәгаен кыйлына. Ләкин, аңлашылган мәгънәләрнең нечкәлекләренә, аларга салынган эчтәлеккә төшенгәндә бары тик гарәпләрнең зәвыклары, теләкләре хакимлек итәргә, өстенлек итәргә тиеш түгел булса кирәк. Бөтен кешелек дөньясы өчен шәригать буларак, ягъни яшәеш кануны буларак иңдерелгән Коръәннең хөкемнәренә бәдәвият [чүлләрдә күчмә тормыш итүчеләр] дөньясында гомер итә торган гарәпләрнең зәвыклары гына нигез була алмый*».

Галимнең бу хезмәте үзенең кызыклы булуы белән бәрабәр безнең көннәр өчен гаять актуаль булуы сәбәпле, аның тулы тәрҗемәсен китабыбызда аерым бүлеге итеп бирдек[1].

«***Дәүләт Думасында мәет якмак мәсьәләсе***»[2] («Дәүләт Думасында мәетләрне яндыру мәсьәләсе») исемле хезмәт – шулай ук Думага кертелгән бер канун ляихәсе белән бәйле рәвештә язылып, кульязмасы 1914 елның 10 апрелендә тәмам булган. 1913 елда Русия Дәүләт Думасында мәетләрнең җәсәдләрен крематорияләрдә яндырып көлгә әйләндерү турындагы закон проекты карала. Думадагы мөселман фракциясе вәкилләре, Муса әфәндегә мөраҗәгать итеп, әлеге әһәмиятле һәм котылгысыз рәвештә мөселманнарга да кагылачак канунга карата шәригать белгече буларак фәтва игълан итүен үтенәләр. Муса әфәнде эшне озакка сузмыйча, тиз арада фәтване бастырып та чыгара. Иң элек ул үлгән кешеләрнең җәсәдләре җиргә күмелергә тиешлеге турында дәлилләр китерә: «*Кеше үзенең күзаллаулары белән, үзенең белдеге белән эш кылганда җинаять кыла алса да, табигатьнең күрсәтмәсе белән хәрәкәт иткәндә, күпчелек очракларда, дөрес эш эшләгән булып чыга. Табигать бары тик кешеләрне генә түгел, бәлки бөтен җан ияләрен дә аларның мәслихәтләренә*[3] *юнәлтә. Ихтыяри эшләрдә яманлык була алса да, табигатьнең юнәлтүе, табигатьнең күрсәтмәсе һәрвакыт һидаять*[4] *була. Бу хакыйкатьнең ышанычлы шаһитлары Коръән кәримдә дә бар. Мәсәлән: «әл-Маъидә» сүрәсендә 30–31нче айәт кәримәләрдә кешеләрнең игътибарларына гаять ачык бер шаһит тәкъдим ителгән: «**Аңа аның нәфесе, үзенең кардәшен үтерүне җиңел эш итеп күрсәтте дә ул аны үтерде, шулай итеп ул хәсрәт итүчеләрдән булып китте. Шуннан соң Аллаһ, кардәшенең үлек гәүдәсен ничек***

[1] Карагыз: IV. Маъидә.

[2] Муса Җаруллаһ. Дәүләт думасында мәет якмак мәсьәләсе. СПб.: Тип. М-А. Максутова, 16 б.

[3] мәслихәт – яхшылык, файда.

[4] һидаять – дөрес юлга чыгару; дөрес юлны күрсәтү; дөрес юлдан алып барылу.

***яшерергә кирәк икәнен күрсәтү өчен, җирдә эзләп йөри торган бер карга җибәрде. Ул: «Мин инде шушы карга кебек булып, кардәшемнең үлек гәүдәсен яшерүдән дә гаҗиз калдыммы?» – диде. Шулай итеп ул үкенүчеләрдән булып китте»***[1].

*Бу ике айәт кәримәдә иң әүвәлге инсанның иң әүвәлге эшләреннән ике эше безгә хикәят кыйлынган:*

1*) берсе – үзенең бәрадәрен үтерү җинаяте. Коръән кәримдә бу олы җинаять кешенең үзенә, кешенең теләгенә кайтарып калдырылу гыйбарәсе белән иңгән;*

*2) икенчесе – бәрадәренең җәсәден күмеп кую фикеренә кешенең юнәлдерелүе.*

*Җинаятьләрнең иң олысын кыйла алган беренче кеше һидаятьләренең иң кечкенәсеннән дә гаҗиз калган. Ягъни, бәрадәрен үтерә алган, ләкин табигать тарафыннан өйрәтелгәненә кадәр аның җәсәден күмеп куя белмәгән. Үтерү җинаяте кешенең теләге белән, үз ихтыяры белән, үз белдеге белән кыйлынган иде. Җирләп кую турындагы һидаять исә, табигатьнең юнәлдерүе белән, бер карганың сабак бирүе белән бирелде.*

*Иң беренче «шәһид-е инсаният»*[2] *хөрмәтенә табигать тарафыннан иң беренче кешеләргә өйрәтелгән дәфен кыйлу*[3] *һидаяте башта бер табигый сөннәт*[4] *иде, ниһаять, бөтен кешеләрдә бер милли*[5] *сөннәт булып китте.*

---

[1] Коръән, «Маъидә» (5:30–31). Айәт Габделбарый хәзрәт Исаев тәрҗемәсендә бирелә (карагыз: Габделбари хәзрәт Низаметдин улы Исаев. Коръән Кәрим тәрҗемәсе / Фәнни мөхәррире Ә.К. Бостанов. Казан: Изд-кий дом «Казанская недвижимость», 2018. 552 б.).

[2] «Шәһид-е инсаният» (гарәп./фарс.) – кешелек дөньясының беренче шәһите, ягъни Аллаһка, ул биргән иманга тугры калу, аларга хыянәт итмәү йөзеннән үлемгә дучар ителгән беренче кеше.

[3] дәфен кыйлу – җәсәдне җирдә казылган кабергә салып күмү; җирләү.

[4] сөннәт – гадәт; теге яки бу җәмгыятьтә һәркем тарафыннан кабул ителгән эш яки эш тәртибе.

[5] милли – биредә милли сүзе теге яки бу халыкны, милләтне күздә тотмый, бәлки кешеләрнең һәммәсен дә тереклек итүче аңлы-акыллы мәхлуклар төре буларак күздә тота.

*Сәхабә[1] Өбәйй бин Кәгаб[2] Сәййдел-вөҗүд[3], галәйһиссаләт вә-с-сәлам, хәзрәтләреннән риваят итде:* (الحد لآدم وغسل بالماء وتر افقالت الملائكة هذه سنة ولد آدم من بعده), *ягъни: кешеләрнең бөек бабалары булган Адәм берничә мәртәбә госел кыйлынып дәфен кыйлынды. Мәетләрнең җәсәдләрен госел кыйлып җирләү бабалары Адәмнән соң аның бөтен балаларына да фитрый[4] сөннәт, милли сөннәт булды. Коръән кәрим күпсанлы айәт кәримәләрендә бу фитри сөннәтне раслады, куәтләде һәм вазифа буларак кешеләргә йөкләде…*

*Исән чакта җир йөзендә яшәү кешенең мөкатдәс хокукыдыр. Үлгәннән соң җир эчендә җәсәднең урын алуы да кешенең мөкатдәс хакы булып чыга. Йортларның кешеләргә мөнәсәбәте нинди булса, каберләрнең дә мәетләргә мөнәсәбәте шундыйдыр. Торган йортыннан кешене чыгару, йортыннан мәхрүм итү тыелган булса, аның җәсәден кабердән мәхрум итү дә тыелган булып чыга*»[5].

Әмма китапның әһәмияте җәсәдләрне дәфен кылуның фарыз дәрәҗәсендәге бер гамәл булуын дәлилләү белән генә чикләнми. Китапта әлеге мәсьәләгә караган саф фикъһый нечкәлекләр дә бәян ителә, мәсәлән, дәфен кылуның важиб булуы һәм шуның нигезләре. Бу хакта язылганнардан аңлашылганча, җәсәдләрне җирләү белән аларны крематорияләрдә яндыруны чагыштырганда, җирләү бик күп яссылыкларда, шул исәптән тирә-як мохитне саклау җәһәтеннән дә отышлырак булып чыга. Моннан тыш, китапта кабер, җәсәдне

[1] сәхабә – Мөхәммәд пәйгамбәрнең (ﷺ) исламны кабул итеп аңа ияргән замандашлары.

[2] Өбәй бин Кәгаб – Мөхәммәд пәйгамбәрнең (ﷺ) милади 649 елда вафат иткән сәхабәсе һәм сәркятибе. Коръәнне матур итеп көйләп укый алганы өчен аны Сәййид әл-курра, ягъни Коръән укучыларның әфәндесе дип атый торган булганнар.

[3] Сәййдел-вөҗүд (гарәп.) – Барлык Галәмнең Әфәндесе, ягъни Мөхәммәд пәйгамбәрнең (ﷺ) мактаулы олуг мәртәбәсен белдерә торган атама.

[4] фитрый – кешегә тумыштан ук хас булган сыйфатлар, мәсәлән, Аллаһка тартылу, гаделлекне гаделсезлектән аера белү һ. б. ш.

[5] Өзек хәзерге татар теленә тәрҗемә ителеп бирелде.

җирләү йоласы, каберстан вә зиратларны тәртиптә тоту хөкемнәре һәм башка байтак әһәмиятле нәрсәләр бәян ителгән.

Асылда, Муса әфәнде бу китабында мөселманнарның үлгәннән соң җирдә казылган каберләргә урнаштырылып, исламча дәфен кылыну хокукларын икеләнүләргә урын калдырмаган сурәттә яклап чыга.

***

1914 елда дөнья күргән «***Бөек мәүзугларда уфак фикерләр***»[1] («Зур темаларга караган вак фикерләр») китабы турында «Шура» журналы сәхифәләрендә белдерү басылган: «*«Бөек Мәүзугларда уфак фикерләр» исемле бу әсәрдә мөхтәрәм Муса әфәнде тарафыннан тәртиб иделүб Мисыр принсесларыннан сәййидә Кадрия ханым Хөсәен хәзрәтләре исеменә тәкъдим иделмешдер. Әсәрнең мәүзугысы Уфа шәһәрендә мәдрәсә-и Галия мөдәррисләрендән Зыяэтдин әл-Кәмали әфәнде тарафыннан тәртиб иделгән «Дини тәдбирләр» исемле әсәрене интикад кыйлудан гыйбарәтдер. Галимләр вә гомумән олуг адәмләр ошбу ике галимемезнең әсәрләрене мөхакәмә кыйлуб файда алырлар, гомум халыкларымыз монларның моназара кыйлышу ысулларындан гыйбрәт алуб файдалансалар кирәк. Тәрбияле вә әдәбле галимләрнең моназаралары да [...]е вә тәрбия кагыйдәләренә ригаяле булачагы мәгълүм*».

[1] Муса Җаруллаһ. Бөек мәүзугларда уфак фикерләр. СПб.: Типография М-А. Максутова, 1914. 32 б.

Китап Зыяэтдин хәзрәт Кәмалиның[1] 1913 елда басылып чыккан «*Дини тәдбирләр*»[2] («Дини чаралар») исемле китабына тәнкыйть буларак язылган. Камали хәзрәтләре күтәргән мәсьәләләр арасында Муса әфәнденең игътибарын җәлеп итеп, аны тәнкыйть сүзен әйтергә этәргәннәре китапның эчтәлегеннән күренә. Биредә «*каләм ияләренә бер үтенеч; «әл-фәкъру фәхри»* [фәкыйрьлегем горурлыгымдыр] *сүзе хакында; «кад кәдәл-фәкъру күфран»* [фәкыйрьлек аздан гына көфер булмый торыр] *сүзе хакында; «ихтилафү үммәти рахмә» [*өммәтемнең төрлелеге рәхмәттер] *сүзе хакында; кешеләрнең фәрештәләрдән өстен булуы турында; Адәмнең гыйсьяны; яхшылыкның акылга вә шәригатькә каршы килмәве турында; хәрам булган нәрсә ризыкмы, түгелме?; Коръән кәрим мәхлүкъ түгел; Ислам хилафәте хакында; Нәбий-е ислам* (ﷺ) *хәзрәтләренең атасы-анасы хакында; раһбәният* [монахлык] *хакында; тәсаввыф хакында; «һувә»* [Ул] *сүзе хакында; акылның һәм барлык галәменең үзара мөнәсәбәтләре хакында җиде фикер; могъҗизаларның хакыйкыйлыгы, фән карашында могъҗизаларның кыйммәте; исламияттә могъҗизаларның кыйммәте; исраъ, мигъраҗ кебек вакыйгаларның тәрбияви әһәмияте; Коръән кәримдә искә алынган Гареше Билкыйс кыйссасы; исраъ, мигъраҗ вакыйгаларының хакыйкыйлыгы; исраъ вә мигъраҗның өндә булуы һәм моның дәлилләре; дини корылтайлар; Коръән кәрим тәрҗемәсе хакында*» кебек темалар бәхәс үзәгенә куелган. Бу исемлектән

[1] Зыя әл-Кәмали (Пәрвазетдин углы Зыяэтдин Камали, 1873–1942) – күренекле дин галиме, фәлсәфәче, җәмәгать һәм татар милли мәгарифенең күренекле эшлеклесе; дини белемне Каһирәдәге Әл-Әзһәр университетында сабакташы Муса Бигиев белән бергә ала; Русиягә кайтканнан соң, 1906 елда Уфада «Галия» мәдрәсәсенә нигез сала һәм 1919 елга кадәр аның белән җитәкчелек итә; Уфада 2 нче җәмигъ мәчете имамы була; 1919–1937 елларда Оренбург диния нәзарәтендә казый булып хезмәт итә; өч томлы «Фәлсәфә-и исламия» («Ислам фәлсәфәсе») исемле күләмле хезмәт авторы.

[2] Зыяэтдин әл-Кәмали. Дини тәдбирләр. Исляхат диния көтебханәсендән беренче китаб. Уфа «Шәрык» матбагасы бәрадәран Кәримовларның, 1913. 88 б.

күренгәнчә, китапта үтә дә әһәмиятле дини, дини-фәлсәфи, игътикади, фәлсәфи, тарихи, әхлакый һәм башка даирәләргә караган, бүген дә кызыклылыгын һәм әһәмиятен югалтмаган, әле дә кызу бәхәсләр уятырлык көч вә киеренкелеккә ия булган мәүзуглар игътибарга алына.

Мисал өчен китаптан бер-ике мисал китерик. «*Каләм иyaләренә бер үтенеч*» исемле кереш сүздә Муса әфәнде шушы тәнкыйть әсәренең язылу сәбәпләрен ачыклап, болай дип яза: «*Мөхтәрәм мөдәррис Зыя әфәнде әл-Кәмали*[1] *хәзрәтләренең «Аллаһ гадәләте»*[2] *исемле әсәрен моннан берничә ел элек юлда, поездда барганда укыган идем. Яңа гына басылып чыккан яңа әсәрләрнең һәрберен, мөмкин булса, алам һәм укыйм…*

*Хөрмәтле вә мәшһүр мөдәрриснең хөр каләме белән язылмыш әсәрләр шәкертләрнең дә, имам әфәнделәрнең дә фикерләренә, карашларына, әлбәттә, тәэсир итә ала. Шуңа күрә, мөхтәрәм галимнең ихтирам ителергә тиешле булган хәтерен гомум җәмәгатьчелекнең хәтере хөрмәтенә фида кыйлып булса да, «Дини тәдбирләр» исемле яңа чыккан әсәрнең эчтәлегенә кагылышлы тәнкыйтемне мәҗбүри сурәттә яздым.*

*«Дини тәдбирләр» мөәллиф әфәнде тарафыннан һәдия буларак, быел гыйнуар аеның унысында миңа иреште. Баштан ахырына кадәр игътибар белән укып чыктым. Уртача үлчәмле, 75 сәхифәдән гыйбарәт булган бу әсәрнең 73 сәхифәсендә тәдбир*[3] *булырлык бер нәрсә дә күрмәдем. Китапта күтәрелгән мәсьәләләр гаять олы булсалар да, мөхтәрәм мөәллиф әфәнденең каләме белән язылмыш сүзләр, фикерләр, мәсьәләләрнең әһәмиятләре, мәүзугларның зурлыгы белән чагыштырганда, гаять гади, хәтта вак булып чыктылар*»[4].

[1] Зыя әл-Кәмали – «Шәхесләр турында белешмә»не карагыз.

[2] «Аллаһ гадәләте» («Аллаһның гаделлеге») – карагыз: Зыяэтдин әл-Кәмалинең әсәре: Камали З. Аллаһ гадәләте. Фәлсәфә исламиядән 1 нче кисәгенә ляхикъ.– Уфа: Каримов, Хусаинов и К°.– 1911. 53 б.

[3] тәдбир – чара; нинди дә булса мәсьәләне хәл итәр өчен эшләнергә тиешле эш.

[4] Муса Җаруллаһ. Бөек мәүзугларда уфак фикерләр. Б. 3–4.

Муса әфәнде игътибар үзәгенә үтә дә әһәмиятле дини мәсьәләләрне куя. Алар арасында үз вакытында ислам дөньясында кан коюларга китергән Хилафәт (Ислам дәүләте) кебек дини-сәяси, тәсаввыф кебек дини-практик, Коръәннең мәхлук (барлыкка китерелгән) яки гайре мәхлук (барлыкка китерелмәгән) булуы, исламияттә могъҗиза төшенчәсе кебек дини-игътикади мәсьәләләрне атап булыр иде. Китапта каралган барлык проблемалар ислам дини фикере даирәсендә әлегә кадәр дә әһәмиятен югалтмаганнар Китабыбызның махсус кушымтасында Муса әфәнденең исламда могъҗиза төшенчәсенә багышланган үтә дә кызыклы фикерләрен китерербез[1].

Муса әфәнденең бу китабы, әлбәттә, татар зыялыларының игътибарыннан читтә калмый. Мәсәлән, Әхмәд-Һади Максудов «Йолдыз» гәзитенең «Яңа әсәрләр» рубрикасында мондый сүзләр язган: «*Муса әфәнде үзлегеннән дә бик күп мәсьәләләр мәйданга чыгарды. Низаглы мәсаъил диниянең күбесен фән вә заманга муафыйк рәвештә хәл вә бәян кыйлды. Бу хосуста Муса әфәнде лүзүменнән зиядә либераллык күрсәтте вә шул сәбәптән әхкям динияне фән вә заман агышына тәтбикъ итүче галим исемен алды да. Моның өчен, әлбәттә, күп җәсарәт вә фидаъилык ляземдер. Бу бабта Муса әфәнде кусур кыйлмады, зур сөбат вә гайрәт күрсәтте. Ләкин бу либераллык Муса әфәнденең үзе табып чыгарган мәсьәләләренә генә махсустыр. Башка галимнәр тапкан мәсьәләләр хакында Муса әфәнде бам-башкадыр. Либерал голямәбез Муса әфәнде генә түгел, әмсале, әлхәмде лиллаһ, бардыр. (Зыяэтдин әл-Кәмали) шул җөмләдәндер. Мәсләкләре бер булган бу ике галим бер-берен мөкавви, бер-берсенә фикердә ярдәмче булырга тиешлегендә шөбһәз юктыр. Ләкин ни өчендер, Зыяэтдин әфәнде башлап язган мәсьәләләрнең һәммәсендә либерал Муса әфәнде тәмам бер фанатиктыр. Ни тапса таба, Муса әфәнде Зыя әфәнде чыгарган фикерләрне гәзитәләрдә дә, китапларында да, мөмкин кадәр җәрех вә кадәх кыйлырга тырыша*».

[1] Карагыз: III Бүлек. 10: «Могъҗиза».

Алга таба язмасында Әхмәт-Һади әфәнде «Уфак фикерләр»дә Зыя Кәмалине тәнкыйтьләүгә багышлаган урыннарның кайберләрен атап чыга да, мондый сүзләр белән мәкаләсен җөпләп куя: «*Димәк, мәшһүр либерал вә реформатор Муса әфәндебез иске хөр фикерләреннән кайтмыш вә тәүбә итмештер. Искеләрнең һөҗүменәме, йә башка бер хискәме мәгълүб булып, тәкъвалык вә диндарлык тарафын куәтли башламыштыр. Бу юлда китәр исә, Муса әфәндинең яңа мөритләре бик күбәер, әмма иске мөритләре нишләрләр икән? Муса әфәндинең ихраранә батыраюына кызыгып мөрит булганнар изтыйрабка төшмәсләрме икән?*»[1]

Ниһаять, 1914 елда чыккан тагын бер китапка – бу юлы 56 сәхифәле «***Мөляхәза***»гә дә игътибар итик. Исеме бик кыска булып күренсә дә, төп нәсхәдә ул мондый рәвештә китерелә: «***Остаз мөхтәрәм Риза әфәнде хәзрәтләренең «Дини, иҗтимагый мәсьәләләр»енә интикад мөнәсәбәтейлә (берничә) мөляхәза***»[2] («Хөрмәтле остаз Риза әфәнде хәзрәтләренең «Дини, иҗтимагый мәсьәләләр»енә тәнкыйть мөнәсәбәте белән (берничә) фикер»).

Китапның гонванында ук игътибарны җәлеп иткән тагын бер нәрсә бар. Муса әфәнде анда мондый сүзләрен урнаштырган: «*«Тәрҗеман» мөхәррире мөхтәрәм остаз Исмәгыйль бәк хәзрәтләренең (1332 сәнә, зөлкагъдә 4 дә, 1914 сәнә сентябрь 11 дә*[3]*) вафаты хатирәсенә*». Шулай итеп, Муса әфәнде бу китабы белән гомерен Русиядә яшәгән мөселман төрки халыкларны уятуга, мәгърифәтле, белемле итү эшенә фида

[1] Әхмәт Һади Максудов. Уфак фикерләр // Йолдыз. 1914, № 1224. 9 июль.

[2] Муса Җаруллаһ. Остаз мөхтәрәм Риза әфәнде хәзрәтләренең «Дини, иҗтимагый мәсьәләләр»енә интикад мөнәсәбәтейлә (берничә) мөляхазә. Петроград: Типография М-А. Максутова, 1914. 56 б. (1914 елның август аенда Беренче бөтендөнья сугышы башлануы аркасында шәһәрнең нимесчә яңгыраган Сант-Петербург исеме II нче Николай патшаның указы белән урысчалаштырылып Петроградка алыштырыла. Бу вакыйга китапның чыгарылыш мәгълүматында да чагыла).

[3] Яңа ел исәбе белән дата сентябрь аеның 24 енә туры килә.

кылган олуг зат – Исмәгыйль Гаспринскийга үзенчәлекле һәйкәл дә куйган.

Риза хәзрәт Фәхретдиннең искә алынган «*Дини вә иҗтимагый мәсьәләләр*»[1] исемле әсәре 1914 елда Оренбургта 208 сәхифәле китап рәвешендә нәшер ителә. Шәркыятьче галимнәр һәм татар иҗтимагый фикере тарихын өйрәнүче белгечләр Риза хәзрәтнең бу китабын аның мирасында төп дини хезмәт дип ассызыклыйлар. Шуңа күрә Муса әфәнденең шул китапка карата тәнкыйть язуы кыю адым икәнлеген һәм никадәр тирән эчтәлекле булуын истә тотарга кирәк. Беренчедән, Муса әфәнденең кыска вакыт эчендә яңа чыккан китапка нисбәтән җавап язып бетергәнен әйтми узып булмый: Риза хәзрәт тарафыннан бандероль буларак җибәрелгән «*Дини вә иҗтимагый мәсьәләләр*» Муса әфәнде кулына 1914 елның 25 августында килеп керә, ә инде сентябрь аеның 11 ндә «Мөляхәза»нең кульязмасы тәмам була. Риза хәзрәттән килгән бүләкне Муса әфәнде алган көндә үк, бер төн эчендә укып чыга: «*Кыйтгасы*[2]*, сәхифәләренең саны җиһәте белән тәмам «Озын көнләрдә рузә» кадәр булган шу китабның мөталәгасына*[3] *шоруг идүб*[4]*, иртә дүртләрдә тәмам итдем; истирахәт*[5] *сәгатьләрене истисна идәр исәк*[6]*, җиде-сигез сәгатьдә укуб чыкдым. Ягъни китаб ләззәт белән, рагъбәт*[7] *белән моталәга кыйлынур дәрәҗәдә гаять гүзәлдер, гаять мөфиддер*[8]»[9].

Муса әфәнде тәнкыйть иткән мәсьәләләр 45 маддәдән гыйбарәт. Алар арасында, әлбәттә, дин һәм иҗтимагый тормыш мөнәсәбәтләре, фикъһы һәм усулы фикъһы, ягъни хокук ме-

[1] Ризаэтдин бине Фәхретдин. Дини вә иҗтимагый мәсьәләләр. Оренбург: «Вакыт», 1914. 208 б.

[2] кыйтгасы – форматы; зурлыгы.

[3] моталәга – язма текст уку.

[4] шоруг идүб – башлап.

[5] истирахәт – ял итү; ял.

[6] истисна идәр исәк – төшереп калдырсак.

[7] рагъбәт – нык теләк; көчле кызысыну.

[8] мөфид – файда китерүче; файдалы.

[9] Өзек хәзерге татар теленә яраклаштырылып бирелә.

тодологиясе, мөселман җәмгыятенең иҗтимагый һәм әхлакый проблемалары, башка кискен хәлләрне игътибарга алган маддәләр, хәтта Коръәннең астрономиягә кагылышлы бер айәтнең тәфсире бар. Мисал өчен, Риза хәзрәт кереш сүзендәге фикерне Коръәннең «***«Сиңа мактаулар булсын! Әйтергә хакым булмаган нәрсәне мин ни йөзем белән әйтим ди? Әгәр мин моны әйткән булсам, Син, һичшиксез, аны белгән булыр идең…***»»[1], дигән сүзләре белән җөпләп куйган. Бу айәтнең авторның әйтергә теләгәненә һәм омтылышларына туры килмәвен ассызыклап, Муса әфәнде болай дип яза: «*Коръән кәримдә әлеге айәт кәримә* «أَأَنتَ قُلتَ»[2], *дигән сорауга җавап булып килә. Коръән кәримдәге бу сорау* [әйтелгән] *сүзне инкяр итү өчен түгел, бәлки* [аны] *әйткән кешене ачыклату өчен* [куелган]: «*Сүз әйтелгән. Ләкин синме ул сүзне әйттең? Башкасымы?»,– димәкдер.*

*Гарәп телендә* «أَأَنتَ قُلتَ؟»[3] *җөмләсе белән* «أَقُلتَ أَنتَ؟»[4] *җөмләсе арасында зур аерма бар: сүз әйтелгән булып та, әйтүчесе мәгълүм түгел исә:* «أَأَنتَ قُلتَ؟ ام غيرك قاله»[5] *җөмләсе белән сорау бирелер. Әмма сүз әйтелгәне, әйтелмәгәне мәгълүм түгел исә:* «أَقُلتَ أَنتَ؟ ام لم تقله؟»[6] *җөмләсе кулланылыр. Урыннарын алмаштырып куллану ялгыш була.*

---

[1] Айәтнең тулысы: «Аллаһ әйтте: «И, Мәрьям углы Гайсә! Кешеләргә «Аллаһны калдырып, мине һәм әниемне ике илаһ итеп алыгыз»,– дип синме әйттең? Ул [Гайсә н.с.] әйтте: «Сиңа мактаулар булсын! Әйтергә хакым булмаган нәрсәне мин ни йөзем белән әйтим ди? Әгәр мин моны әйткән булсам, Син, һичшиксез, аны белгән булыр идең. Син минем күңелемдәгене беләсең, мин исә Синең күңелеңдәгене белә алмыйм. Син бит бөтен яшеренне тулысынча белүчесең» (Коръән, 5:116).

[2] ә әнтә культә – синме әйттең? (Коръән, 5:116).

[3] ә әнтә культә – синме әйттең? (Коръән, 5:116).

[4] ә культә әнтә – син әйттеңме?

[5] ә әнтә культә? әм гайру-кә каләһу? – синме әйттең? Яки аны синнән башка берәү әйттеме?

[6] ә культә әнтә? Әм ләм тәкуль-һу – син әйттеңме?

*Коръән кәримдә «قَالَ سُبْحَانَكَ مَا يَكُونُ لِي أَنْ أَقُولَ مَا لَيْسَ لِي بِحَقّ»*[1]*, дигән айәт кәримә: «أ قلت انت للناس؟»* [2]*, дигән сорауга җавап булып килгән булса иде, мөәллиф*[3] *әфәнденең икътибасы*[4] *максатына бәлки туры килер иде. Ләкин айәт кәримәне асыл мәгънәсеннән читләштерү дөрес эш түгел булса кирәк.*

*Гафу итегез, әмма бу тәнкыйтемне тәфсирчеләргә дә, тәрҗемәчеләргә дә юллыйм: тәфсирчеләрнең дә һичбере, тәрҗемәчеләрнең дә һичбере гарәп теленең нечкәлекләренә, үзенчәлекләренә күбесенчә игътибар итми, бәлки һәрвакыт санга сукмый.*

*Ибне Мәрьямне илаһилек дәгъва итүдән арындыру максат итеп куелса: «أ قُلتَ أَنتَ؟»*[5]*, дип сорау тиеш икән, ни өчен «أ أَنتَ قُلتَ»*[6]*, дигән сорау сайланылган?*

*Ул сүздән үзенең пакьлеген исбат итү өчен: «لو قلته لعلمته»*[7]*, кебек искәрмәле шарт җөмлә куллану тиеш икән, ни өчен: «إِن كُنتُ قُلْتُهُ فَقَدْ عَلِمْتَهُ»*[8]*, дигән вәзгыясе ихтийар кыйлынмыш? Телнең мондый үзенчәлекләренә тәфсирчеләрнең, тәрҗемәчеләрнең һичбере игътибар итмәгән.*

«أ أَنتَ قُلتَ لِلنَّاسِ»[9] *дәлиллегенә күрә, ул сүзне әйтүчеләрнең берсе, әлбәттә, әйткән булган. Ләкин Коръән кәримнең шаһидлыгына күрә, Ибне Мәрьям андый сүзләрдән, әлбәттә, пакьтер. Алай булса, ул сүзне кем әйткән? Бу тарихи хакыйкатьне тикшереп, исбат итү тәфсирчеләргә, әлбәттә, тиеш иде. Ләкин әһле тәфсир мондый нәрсәләргә игътибар итми.*

---

[1] «Ул [Гайсә н.с.] әйтте: «Сиңа мактаулар булсын! Әйтергә хакым булмаган нәрсәне мин ни йөзем белән әйтим ди?» (Коръән, 5:116).

[2] ә культә әнтә ли-н-нас? – кешеләргә син әйттеңме?

[3] мөәллиф – әсәр язучы, автор.

[4] икътибас – өземтә, цитата.

[5] ә культә әнтә ли-н-нас? – кешеләргә син әйттеңме?

[6] ә әнтә культә – синме әйттең? (Коръән, 5:116).

[7] ләү культу-һу лә-галимтә-һу – аны әйтсәм, син, әлбәттә, инде белер идең.

[8] «Әгәр мин моны әйткән булсам, Син, һичшиксез, аны белгән булыр идең» (Коръән, 5:116).

[9] «кешеләргә… синме әйттең?» (Коръән, 5:116).

*Һәрбер әсәремдә һәммә тәфсирчеләрне күпсанлы айәт кәримәләрдә ачыктан-ачык тәнкыйть иттем. Ул тәнкыйтьләремдә дөреслеккә ирешмәгән булсам, шат булыр идем. Чөнки тәнкыйтьләремнең күбесе бәян итү кануннарына, бәлягать*[1] *кануннарына таяна иде. Ул кануннарны белмәү миңа бәлки гаеп түгелдер, ләкин бөек тәфсирчеләрнең мәртәбәләренә лаек булмаса кирәк*» (Мөляхәза, б. 3–5).

Муса әфәнденең тел белгече буларак җөмлә төзелешенә кагылышлы бу фикерләре, беренче карашка, бик тар, тик синтаксистларны гына кызыксындырырлык булып күренә. Әмма чынлыкта Бигиевнең аңлатмалары, бер яктан, аның Коръәннең мәгънәви нечкәлекләрен никадәр тирән аңлаган булуын күрсәтсә, икенче яктан, бик җитди тарихи һәм фәлсәфи нәтиҗәләргә китерә, һич югында, аек акыл ияләрен шул турыда уйланырга этәрә. Андый фикерләр, нәтиҗәләр, идеяләр китапта күп. Мисал өчен, «бу – дөньяви, монысы – дини», дип аеруның ялгыш булуы турындагы сүзләрен китерергә мөмкин: «*Безнең исламият – хәят динедер; безнең шәригать – иҗтимагый-мәдәни шәригатьтер. Хәят белән исламият арасында киртә юк. Исламият даирәсе хәят даирәсе кадәр киңдер. «Дини мәсьәлә», «дөньяви мәсьәлә» кебек гыйбарәләр – ягъни хәят белән исламиятне берсен икенчесеннән аеру нигезенә корылган гыйбарәләр – безгә килешә торган нәрсә түгел.*

*Дөрес, чиркәүне – дәүләттән, «религия»не хәяттән аеру теләкләре Көнбатыш дөньясында бәлки бардыр. Дөрес, исламият даирәсе фикъһы китапларыбыз, әхлак китапларыбыз даирәсе кадәр генә булса иде, без дә моңа мәҗбүр булыр идек. Ләкин алай түгел. Исламият хакында күбебезнең игътикады бәлки шундыйдыр. Ләкин исламият мәртәбәсенә туры килгән хакыйкать бу игътикадның артындадыр.*

*Остаз мөхтәрәм мөәллиф әфәнде китапның 8 нче һәм дә мөтәгаддид сәхифәләрендә исламиятне – хәяттән, динне дөньядан аеру нигезенә корылган фикерләрен язган. Хөкем ике төрле: берсе – «дини эш», икенчесе – «дөньяви эш». Әхлак та ике төрле: берсе – «шәригатьчә әхлак», икенчесе – «көнку-*

[1] бәлягать – сүзнең, сөйләмнең дөреслеге, матурлыгы, төзеклеге.

*реш әхлагы». Канун да ике төрле: берсе – «ясалма канун», икенчесе – «шәригать». Адәм баласының хәяте белән дине арасында һәр нәрсәдә шундый икетөрлелек бар булып чыга. Аларның берендә кеше ирекле, үзгәрә һәм үзгәртә ала; икенчесендә кешенең хакы юк, ихтыяры юк, биредә ул һичкайчан ни үзгәрә, ни үзгәртә алмый.*

*Беләмен ки, күпчелекнең карашы һәм ышануы шундый. Остаз мөхтәрәм мөәллиф әфәнде хәзрәтләре дә күпчелекнең ышануына ияргән. Исламияткә, шәригатькә кәлямчыларның, усулчыларның күзе белән карасак, андый ышану безгә дә мәҗбүри төстә бәлки тиеш булыр. Ләкин минем күзем, минем карашым тәмам башкадыр.*

*Исламиятне һәр хосуста хәяттән, мәдәнияттән аеру-аермау – безнең карашыбызга иярә торган бер хәлдер: әгәр исламиятне бүгенге фикъһы, бүгенге әхлак даирәләре белән чикләсәк, исламиятне хәяттән, мәдәнияттән аеруның зарурилыгына бәлки мәҗбүр булырбыз. Ул чакта «шәригать»не ташлап, Америка хөкүмәтләренең «ясалма кануннары»н алу хурлыгына төшәчәкбез; яки Ибне Халдун кебек «акылга нигезләнгән сәясәт» һәм «дингә нигезләнгән сәясәт» төшенчәләрен уйлап чыгару хәйләсе белән ислам шәригатен «исәпкә алмау шүрлекләренә» урнаштыру юлларын әзерләгән булырбыз.*

*Ләкин исламиятнең хәят даирәләре, акыл даирәләре, тәрәккъыять даирәләре кебек гаять югары, гаять киң дин булуын аңласак һәм танысак, ул чакта исламиятне хәяттән, мәдәнияттән аеруның кирәге калмаячак, бәлки хәят өчен, тәрәккъыять өчен, бәхет өчен кирәк булган һәрнәрсә, шуңа ирешер өчен эшләнәсе һәммә эшләр исламиятнең нигез ташы кебек булыр. Ул чакта «хәятле дин, динле хәят», «көчле исламият, исламиятле көч» барлыкка килер»*[1].

Гомумән, Муса әфәнденең «*Остаз мөхтәрәм Риза әфәнде хәзрәтләренең «Дини, иҗтимагый мәсьәләләр»енә интикад мөнәсәбәтейлә (берничә) мөляхәза*» исемле бу хезмәте, бер яктан, XX гасыр башы татар дини-яңарыш әдәбиятында

[1] Муса Җаруллаһ. Мөляхазә, б. 9.

үзенчәлекле урын алып тора, икенче яктан, ул бүгенге көндә дә үзенең актуальлеген югалтмаган.

## Инкыйлаб алды еллары

1915 ел – Муса әфәнде инде ничә ел Петроградта мул итеп төзелгән иләмсез зур биналардан берсенең түбәсе астына поскан кечкенә мансардада яшәп ята. Олуг галим белән аралашу мәртәбәсенә ия булган Галимҗан Идриси үзенең истәлекләрендә бу бүлмә турында мондый сүзләр язып калдырган: «*Бу бөек кешенең һич тәртипкә китерелмәгән кечкенә бүлмәсе зур җилдләр (томнар) белән, гарәпчә, төрекчә, русча китап һәм кульязма әсәрләр белән тулы иде*»[1].

1915 елның февраль аенда Муса әфәнде Оренбургка барып, Диния нәзарәтендә имамлыкка указ алыр өчен имтихан тапшыра. Март аенда Петроград мөселманнары җыен үткәреп, хөрмәтле галимне Беренче мәхәллә мәчете имамы итеп сайлыйлар. Петроградның беренче мәхәллә мәчете дигәндә сүзнең әле дә шәһәрнең йөзек кашы булып торган Җәмигъ мәчет турында барганын аңларга кирәк. Бу адымнары белән Петроград мөселманнарының өстенлек алган бер өлеше симпатияләренең Муса әфәнде Бигиев кебек алдынгы карашлы, мөҗәддид рухлы, дини һәм дөньяви белемнәргә ия булган, чит телләр белгән муллалар тарафында булуын күрсәткәннәр. Әмма дәүләт түрәләре ул чакта төзелеше әле тәмамланып бетмәгән булачак Җәмигъ мәчетнең имамы итеп һич тә Муса әфәнде булуын теләмиләр.

Ул арада мөфти Мөхәммәт-Шәриф углы Мөхәммәдъяр Солтанов (1837–1915) хәзрәтләре вафат була һәм хөкүмәт аның урынына Санкт-Петербург ахуны һәм Петербург хәрби округы имамы буларак үзен империянең турылыклы хезмәтчесе буларак танытып өлгергән Гатаулла углы Мөхәммәт-Сафа Баязитовны куя. Әлеге вазгыять Муса әфәнденең планнарына да тәэсир итә: бу шәхеснең кулы астында имам булып

---

[1] Канлыдәрә китабыннан: Kanlıdere, Ahmet. Kadimle Cedit Arasında Musa Cârullah. Hayatı/Eserleri/Fikirleri. Ankara: Dergâh Yayımları: 2005. S. 89.

эшләүдән ул баш тарта. Муса әфәнде Уфада чыга торган «Тормыш» гәзитендә күләмле мәкалә бастыра, Сафа Баязитовка үзенең тискәре мөнәсәбәтен бер җөмлә белән диярлек бик кискен сурәттә белдерә. Мәкаләнең калган өлешендә ил өчен канын да, җанын да аяусыз сугышта фида кылган мөселманнарга карата Русия хакимияте алып барган сәясәтнең начар булуы күрсәтелә, мөфти билгеләү мәсьәләсендә мөселманнарга аз гына булса да ихтирам белдерү йөзеннән бу эшне үз ихтыярларына тапшырмавы өчен тәнкыйтькә тотыла. Бу материал дәүләт белән мөселманнар арасындагы күңелсез вазгыятьне фаш итү буларак кына түгел, аны, эчке киеренкелегенә һәм үтә дә тәэсирле тел белән авторның кызу хисләрен чагылдыруына бәйле, Муса әфәнденең үзенә күрә сәяси манифесты, җан фөрьяды дип тә кабул итәрлек. Дәүләт тарафыннан «ят диннәр»нең берсе булган ислам динен тотучы татарның уй-ниятләрен һәм йөрәк тибешен күзәтеп торырга тиешле чиновниклар әлеге документны, әлбәттә, игътибарларыннан читтә калдыра алмыйлар – аны урыс теленә тәрҗемә итеп, тиешле досьеларына беркетеп куялар[1].

Сүз уңаеннан, әлеге шәхесләр арасындагы мөнәсәбәтләргә яңа төс өстәгән һәм Муса әфәнденең холкын яхшырак аңларга мөмкинлек биргән бер документ белән уртаклашасым килә. 1923 елда кулга алынып төрмәдә утырган чагында Муса әфәнде допрос протоколларының берсендә менә мондый сүзләр язып калдырган: «*А Сафа Баязитова очень давно знаю. Никогда не был моим другом, а преследовал меня, чем мог. Но я никогда ему не отвечал. А, когда после февральской революции он пал и очутился в трудном во всех отношениях положении, он ни у кого не находил поддержку, кроме меня. Такое мое поведение в отношении моем к Баязитову просто объясняется моей природой. Я обыкновенно так отношусь ко всему народу, кто ко мне обращается со своей нуждой*».

[1] Тагирджарова, күрс.хезм. Б. 453.

Муса әфәнде, гомумән, Русиягә кайтып Габдерәшит казый белән хезмәттәшлек итә башлаган көненнән Охранка[1] күзәтүе астында булган.

Өстәвенә, Бигиев иҗатының күркәм бер җимеше булырга торган чираттагы китабы да дөнья күрми кала. Сүз аның «***Исляхат әсасләре***»[2] («Яхшырту нигезләре») турында бара. Китап басмаханәдән чыга, әмма сугыш сылтавы белән мөселманнарга карата репрессияләрен арттырган хөкүмәт карары белән аның тиражы юкка чыгарыла. Әгәр Муса әфәнде берничә данәсен яшереп калмаган булса, без, мөгаен, аны югалткан булыр идек.

Әмма тәкъдир Муса әфәндене моннан күпкә авыррак сынауларга юлыктыра – шул ук 1915 елның июнь аенда аның Гайшә исемле сабый кызы кисәк кенә авырып китеп, бер көн дигәндә җан бирә… Сүз дә юк, Муса әфәнденең гаиләсе өчен дә 1915 ел бик авыр хәсрәтле ел була.

«***Исляхат әсасләре***»нә әйләнеп кайтыйк. Исеменнән аңлашылганча, әсәр 1914 елда Петербургта үткәрелгән Рәсми җәмгыять (ягъни, мөселман корылтае) мөнәсәбәте белән язылган. Китап кыйммәтле тарихи чыганак булып тора, чөнки аның сәхифәләрендә, Муса әфәнденең шәхси фикерләре белән бергә, 1904–1915 елларда Русия мөселманнарының иҗтимагый хәрәкәтләренә кагылышлы барлык документлар җыелган. Моны аңлар өчен әсәрнең титул битендә күрсәтелгән эчтәлеккә күз ташлау да җитә: «*1) Русия мөселманнарының 11–12 еллык хәрәкәтләренең бөтен җимешләре, 2) ляъихәләрдә[3], петицияләрдә бәян кыйлынмыш бөтен таләпләре, 3) ул еллар дәвамында дәгъвәт кыйлынмыш съездлары,*

---

[1] Охранка (Отделение по охранению общественной безопасности и порядка) – Русия империясе Эчке эшләр министрлыгының сәяси тәфтиш (шымчылык) белән шөгыльләнүче структур оешмасының атамасы.

[2] Муса Җаруллаһ. Петербургда 1914 сәнә ийн 15–25-дә рәсми җәмгыять мөнәсәбәтейлә исляхат әсасләре. Петроград, Типография М-А. Максутова, 1915. 288 б.

[3] ляъихә – проект.

*җәмгыятьләре, 4) съездларның мөзакәрәләре*[1]*, һәммә карарлары, 5) мәктәп-мәдрәсәләрнең, мәчет-мәхәлләләрнең, рухани идарәләрнең исляхатына кагылышлы маддәләр, 6)»Закон» мәҗәлләсендә Русия мөселманнарына кагылышлы статьялар, 7) мөһим мәсьәләләр хакында белгечләр тарафыннан язылмыш, әзерләнмеш докладлар, 8) күпсанлы төрле ляъихәләрнең асылы, чыганагы, 9) карарларга, ляъихәләргә, хәрәкәтебезгә карата мөәллифнең*[2] *тәнкыйте, 10) карарларда, ляъихәләрдә күрсәтелгән хаҗәтләр өстенә мөәллифнең өстәмәсе, 11) моннан соң безгә ни кирәк? – бу хосуста бөекләребезнең фикере, 12) ислам шәкертләренең хәрәкәтләре һәм таләпләре*».

Әлеге китапның сугыш көннәрендә язылганын истә тотканда, Муса әфәнденең аны нинди максатны күздә тотып тәкъдим итүе дә аңлашыла: «*Солых көннәрендә мөселманнарның кулында бер әзерлек булыр дигән өмет белән табыг кыйлынды*». Ягъни, китап үткәндә булып узган чаралар турында язылса да, Муса әфәнде аны киләчәккә карап, сугышлар беткәч мөселманнарга кирәге булачагына, файдаланачакларына, дөньяви тәрәкъкыять һәм рухи-әхлакый үсеш юнәлешендә үзгәртәчәкләренә ышанып язган.

Муса әфәнденең әлеге әсәренә бәя биргәндә, мәшһүр татар-төрек тарихчысы мәрхүм Надир Дәүләтнең (1944–2021) «*Бу китап булмаса, без татар милли хәрәкәте тарихын белмәс идек*» дигән сүзләрен хәтергә алырга мөмкин.

Алга таба Муса Җаруллаһның 1915 елда чыккан «***Фикъһу әл-Коръәни***»[3] исемле гарәп телендә язылган гаять үзенчәлекле китабына да туктап алырга кирәк.

Галимнең бу хезмәтен Коръән тәфсиреннән бер парча дип атау дөрес булыр, чөнки аның сәхифәләрендә «Фатиха» сүрәсе тулысынча, һәм «Бәкара» сүрәсенең беренче дүрт аяте тәфсир кылына. Әмма китапның исеменә карап кына

---

[1] мөзакәрә – фикер алышу, дискуссия.

[2] мөәллиф – төзүче.

[3] Муса Җаруллаһ. Фикъһу әл-Коръәни. Петроград: Типография М.– А.– Максутова, 1915. 32 б.

моны аңлап булмый. Чыннан да, ислам динендә «фикъһе» сүзе хокук теориясе һәм практикасын белдерә, бу нәрсәләр белән фәнни төстә шөгыльләнү мәгънәсендә кулланыла. Бу нисбәттә фикъһыны шәригатьнең, ягъни исламча яшәү рәвеше кагыйдәләренең методологик нигезе, хокук гыйлеме дип тә аңларга мөмкин. Шуңа күрә, әгәр «Фикъһу әл-Коръәни» китабы белән турыдан-туры, кулыңа тотып, актарып танышмасаң һәм, өстәвенә, гарәп телен белү дәрәҗәң дә түбән булса, аны Коръәндәге фикъһы мәсьәләләренә багышланган бер хезмәттер дип аңларга мөмкин. Әмма «фикъһу әл-Коръәни» гыйбарәсен болай аңлау гарәп грамматикасы кагыйдәләренә үк туры килми. Гарәп телендә «фикъһ» сүзе, асылда, «тирәнтен аңлау», «әйберләрнең асылын күрү» кебек мәгънәләргә ия булуын истә тотарга кирәк. Китапның эчтәлеге белән танышканнан соң, аның исеме «Коръәнне тирәнтен аңлау» дип тәрҗемә ителергә тиешлеге көн кебек ачык була.

Бу әсәр, Муса әфәнде тарафыннан языла башлаган зур Коръән тәфсиренең бер өлеше буларак кабул ителеп, татарларда тәфсир гыйлеменең бер үрнәге буларак, мәдрәсәләрдә һәм дини институтларда өйрәнелергә лаек.

1916 елны Муса әфәнде, гадәттәгечә, туктаусыз сәфәрләрдә, баш күтәрмичә язуда үткәрә. Әледән-әле хатыны һәм балалары белән өзеп-өзеп кенә күрешеп ала. Ул елларда аның хәләл җефете Әсма ханым балалары белән күбесенчә Чистайда, әнисе янында яши, Муса әфәнде исә – башкалада. Әледән әле ул йә үзе Чистайга барып, анда гаиләсе кочагында берничә көн торып ала, йә Әсма ханым Петербургка килеп, шунда күрешәләр. 1916 елның көзендә шулай була – Әсма ханым ире янына Петербургка килә һәм өч ай вакытын Муса әфәнде белән бергә үткәрә алуы турында шатлыгын эченә сыйдыра алмыйча куен дәфтәре белән серләшә.

Гомумән, Әсма ханымның язмаларыннан, аларның мәхәббәтләренең көчле һәм ялкынлы булуы күренеп тора. Аның көндәлекләре аның күңел түреннән ташып чыккан мондый сүзләрен саклап калганнар: *«22 октябрь, 1914 ел. Мусамны озаттым. Килүе никадәр шатлыклы булса да, ки-*

*түе шулкадәр уңайсыз, күңелсез була, Ходаем сабырлык бирсен... Дөньяда иң авырсынган нәрсәм – Мусамнан аерылып торуым. Күз алдымнан җанашымны бер минутка җибәрмәс идем. Шул кадәр сагынган минутлар була, һичнәрсә күземә күренми, йөрәгем сызлана. Бер минут йөзен күрү өчен әллә нишләр идем. Я, Раббым, аерма шул сөекле, шул газиз җанашым Мусамнан. Сәламәтлек, озын гомер бир җанашыма. Мусамнан мин мәхрүм булмасам иде. Дөньяда һич алышмаслык Мусамның мәхәббәте бар... Моннан артык дөньяда байлыкмы бар, рәхәтме бар... Раббым, гомер ахырына кадәр шуннан мәхрүм итмә*»[1].

Илнең төрле почмакларында яшәргә мәҗбүр булулары сәбәпле Муса әфәнде белән Әсма ханым бер-берсен бик сагынып, очрашуларны зарыгып көтеп яшәгәннәр. Петербургтан Чистайга – балалары янына кайтып китәр алдыннан Әсма ханым куен дәфтәрендә: «*Янә ялгыз калдырам, унике ел борчылу, никадәр арыдым, кайчан гына бергә яши башларбыз икән...*», дип язып куя[2]. Бу ачынулы сүзләрдә телгә алынган «унике ел» гыйбарәсенә тиешенчә игътибар итсәк, Муса әфәнде белән Әсма ханымның 1905 елда башланган гаиләви тормышларының беренче көннән бирле шундый сурәттә дәвам итүе аңлашылачак. Һәм аңлашыласы тагын бер нәрсә – Муса әфәнденең бик сирәк вакытта гына хатыны һәм балаларын Петербургка алып, үзе янында тотарлык кадәр финанс мөмкинлекләренә ия булуы, ягъни дин гыйлеме күгендә исеме тулган ай кебек балкып торган галим әфәндебез һичкайчан бай булмаган, кулына акча кергән очракта да, яртысын гаиләсенә тотып, яртысын мохтаҗларның хаҗәтләренә сарыф итә торган булган. Моның шулай булуы аның НКВД архивларында сакланган күрсәтмәләрендә ярылып ята. Димәк, 1923 елда кулга алынганнан соң дознание анкетасында ул, «никакой собственности не имею» дип, юкка гына язмаган.

---

[1] Фатыйма Бигиева-Таһирҗанова. Әтием хакында хатирәләр // Муса Бигиев: мирас һәм хәзерге заман. Халыкара фәнни конференция материаллары. Казан: Гөлстан, 2000. Б.173.

[2] Тагирджанова А.Н. Күрс.хезм. Б. 113.

1916 елны Уфада «Галия»[1] мәдрәсәсенең ачылышына ун ел тулу тантанасы үткәрелә. Мәдрәсәне Муса әфәнденең дусты, аның белән бергә Мисырда шәкертлек кылган Зыяэтдин хәзрәт Камали ача һәм беренче көннән башлап аның мөдире (ректоры) һәм мөгаллиме булып эшли. Әлбәттә, әлеге җәдитчә ысулга корылган мәдрәсәнең тарихы аерым игътибарга лаек. Алдагы сүзебезнең ни турыда буласын истә тотып, мәдрәсәдә – аның уку-укыту программалары һәм ысуллары яссылыгында, мөгаллимнәр даирәсендә дөньяви һәм дини гыйлемнәр арасындагы балансны җайлау мәсьәләсендә – киеренке процесс барганлыгын искәртеп узам. Дөньявилык өстенлек итә башлаганга күрә, 1915 елда мәдрәсә дөньяви педагогик уку йортына әйләнеп бетә диярлек. Бу эчке үзгәрешләр мөдир урынбасары итеп киләчәктә татар язучысы буларак танылган Галимҗан Ибраһимовның куелуына китерә, мәдрәсәдә татар әдәбияты, әдәбият белеме, татар тел белеме кебек гуманитар агым зур үсеш ала. Мәдрәсәнең юбилей тантанасы әнә шундый атмосферада үткәрелә. Тантанага бөтен Русиядән мөселманнар җыела. Идел-Урал төбәгеннән, башкаладан килгән кунаклар белән бергә, Кавказдан, Кырымнан, Төркестаннан, Себердән килгән кешеләр дә була. Тантанада Галимҗан Ибраһимов чыгыш ясый һәм чыгышында Русиядә

[1] «Галия» мәдрәсәсе – Уфа мәчете каршында 1905–1919 елларда эшләп торган мәдәрәсә. Оештыручысы һәм алышынмас мөдире – Зыяэтдин Камали. 1907 елда мәдрәсә сәүдәгәр Садри Назыйров һәм Тәфкилевләрнең килене Суфия Җантурина-Тәфкилева акчасына Уфимская урамында салынган яңа уку бинасына күчә. 1916 елның 26 декабрендә узган тантаналы җыелышта игълан ителгән ун еллык эш нәтиҗәләренә караганда, «Галия»дә 950 егет укып чыккан, шулардан 224 кеше татар булмаганнар. Укып чыкканннары 28 губернаның төрле дәрәҗәдәге 230 мәктәбендә 17 мең чамасы баланы укытып ятканнар. 38 кеше указлы мулла булып торган, 14 – гаскәри мулла, 29 кеше ул вакытта инде сәнгать әһеле булып киткән. 1919 елда мәдрәсә ир балалар мәктәбе итеп үзгәртелә. 1970 елларга кадәр мәдрәсә бинасы 15 нче татар мәктәбе сыйфатында эшләп килгән. Совет чорында «Галия»не тәмамлап чыккан кешеләрнең 70% дәүләт тарафыннан юк ителә.

яшәүче төрки халыклар өчен уртак мәдәният булдыруның мөмкин түгеллеге, болай итәргә тырышуның хата булуы турындагы фикерләрен яңгырата. Тантанада катнашкан Муса әфәнде Ибраһимовка каршы чыгып, төрки халыклар өчен уртак бер әдәби тел барлыкка китерүнең кирәклеге, хәтта зарурилыгы турында сүз әйтә. Аның фикеренчә, һәр төрки халык өчен аерым әдәби тел, аерым әдәбият, аерым мәдәният булдырырга тырышу дөрес эш түгел, зур тарихи хата. Бу җәһәттән, ул Ибраһимовны, хәтта, халыкка хыянәт итүдә гаепли.

Бу вакыйгадан аңлашылганча, Муса әфәнде милли телебез, әдәбиятыбыз, мәдәниятебез кебек халыкны халык иткән, аны берләштерү эшенә хезмәт итә алган ифрат та җитди фәнни һәм, шул ук вакытта, иҗтимагый мәсьәләләрне беркайчан да игътибарыннан калдырмаган. Вакыты җиткәч, ягъни эмиграциядә, Муса әфәнде кайбер илләрдә гарәп әдәби телен сөйләм теленә алыштыру планнарына каршылыгын белдереп, шул илләрнең матбугатында төпле фәнни чыгышлар ясый, үз карашларын яңгыратып, җирле галимнәр белән кызу гыйльми дискуссияләрдә катнаша. Мисырда булсын, башка гарәп илләрендә булсын, әлеге көндә дә әдәби гарәп теле үз урынында калуында Муса әфәнде Җаруллаһ уйнаган рольнең зур булуы бик ихтимал.

1916 елда Муса әфәнденең «***Хокук әсасия (124 статья). 1906 сәнә април 23-дә тәсдыйк кыйлынмыш әсас канунлар***»[1] («Төп хокуклар (124 статья). 1960 ел апрель 23-тә расланган төп кануннар») исемле китапчыгы дөнья күрә. Китапның тышлыгында «Иң соң нәшер кылынмыш канун мәҗәлләсенең беренче җилдендән тәрҗемә» дигән өстәмә дә бар. Асылда бу хезмәт Русия империясендә беренче конституция буларак кабул ителгән «Основные законы, утвержденные 23 апреля 1906 года» исемле ике фасыл, 17 бүлек һәм 223 маддәдән торган дәүләт документының госманлы-татар теленә тәрҗемәсеннән гыйбарәт. Дөрес, тәрҗемәдә маддәләр

[1] Муса Җаруллаһ. Хокук әсасия (124 статья). 1906 сәнә април 23 дә тәсдыйк кыйлынмыш әсас канунлар. Петроград: Типография М-А. Максутова, 1916. 20 б.

саны 124 итеп күрсәтелгән. Бу тәрҗемә 1915 елда басылып чыккан «Исляхат әсасләре» исемле җыентыкта урын алган була. Җыентыкның эчтәлегендә бу документ «Конституция статьялары» дип атала, әмма аның китаптагы тексты «Хокук әсасия» исеме белән бирелә. Шунда ук Муса әфәнде, бу документка карата кыска гына кереш буларак, түбәндәге аңлатмаларын язган: «*...инде тарих тәртибе белән Русиядә конституция мәсьәләләрене бераз бәйан идәем.*

*Дәүләт шурасының Дәүләт думасының 1906 сәнә април 27дә дәгъвәт кыйлыначаклары фиврал 20 указыйлә игълан кыйлындыкдан соң, Русиядә интихаб*[1] *хәрәкәтләре башланды. Съездларымызның карарларына муафыйк*[2]*, Русия мөселманлары да интихаб хәрәкәтләренә иштиракь итделәр*[3]*. У вакыт җәридәләрнең*[4] *тәхминләренә*[5]*, халыкның өмиденә күрә, Дәүләт думасында иллебиш-алтмыш кадәр мөселман вәкил булынмак мәэмүл иде*[6]*.*

*1906 сәнә април 23 указыйлә Министрлар кумитасы илга кыйлынды*[7]*. Һәм дә у көндә дәүләтнең әсас канунлары тәсдыйк кыйлынуб*[8]*, Русиядә конституция тәэсис кыйлынды*[9]».

Инде искә алынганча, цензура «Исляхат әсасләре» җыентыгының таралуына комачау итә. «Основные законы…»ны татарларга ана телләрендә ирештерүгә олы әһәмият биргән Муса әфәнде аны аерым китап итеп бастыра һәм тышлыгында «*Җиде-сигез йөз сәхифәлек «Исляхат әсасләре» исемле китабдан бер кисәк*», дигән сүзләр урнаштыра. Моннан тыш, Муса әфәнде шунда ук: «*Русиядә мөселман гражданларының һәрберенә дәүләтнең әсас канунларыны белмәк тиешдер, йахуд лә әкаль, мөфиддер. Буңа күрә, «Исляхат әсаслары»нда*

[1] интихаб – сайлау.

[2] муафыйк – туры китереп.

[3] иштиракь итделәр – катнаштылар.

[4] җәридәләр – газеталар.

[5] тәхминләр – фаразлар; күзаллаулар.

[6] мәэмүл иде – өмет ителә иде.

[7] илга кыйлынды – бетерелде.

[8] тәсдыйк кыйлынуб – расланып.

[9] тәэсис кыйлынды – нигезләнде; кабул ителде.

*дәреҗ кыйлынмыш «Дәүләтнең әсас канунлары» галә хәддиһи рисалә шәкелендә дә нәшер кыйлынды»*, дип, әлеге китапның язылуы сәбәбен ачыклый.

Китап брошюра кадәр генә булса да, ул XX йөз башы татар җәмәгатьчелегендә хокукый белем таратылуы тарихының бер сәхифәсе буларак кызыклы. Моннан тыш, шул ук дәвердә татар теленә хокукый эчтәлекле документларны тәрҗемә итү үрнәге буларак та зур кыйммәткә ия. Тәрҗемә аспектларына Муса әфәнде үзе дә аерым игътибар биргән. Мәсәлән, документның «Исляхат әсаслары»ндагы редакциясендә аны татарча ни өчен «Әсас канунлар» дип бирүен ул болай дип аңлаткан: «*«Конституция» сүзене «Канун әсасий» сүзейлә тәрҗемә итмәк мәкъбуль улмышдыр*[1]*. Шу тәрҗемә мофрадат*[2] *җиһәтейлә*[3] *һәрникадәр дөрест исә дә, тәркиб*[4] *җиһәтейлә гарибдер*[5]*. Буңа күрә бән тәрҗемәдә төрки тәркибе ихтийар идүб, «Әсас канун» сүзейлә тәрҗемә итдем. «Әсас канунлар» сүзе «Основные Госуд. Законы» сүзенә дә иң муафыйк тәрҗемә улур*».

Документта кулланылган төшенчәләрнең тәрҗемә ителүе темасын дәвам итеп, мисал өчен, хәзерге көндә *Самодержавная Верховная власть* дигән гыйбарәне алыйк: Муса әфәнде аны *Үзирекле иң өстен власть* дип тәрҗемә иткән. Тагын берничә мисал: *права состояния – хокук халия*; *удельные имущества – фамилия нәфәкасенә тәгаен кыйлынмыш әмляк*; *государево имение – сарай милекләре*; *судебная власть – хөкем*. Әмма махсус терминнарны түгел, гади сүзләрне тәрҗемә итүе дә кызыклы: *осуществляет – фигълият бирер*, *гамәлгә китерер*; *почин – шоруг*, *ибтида*, *тәшәббес* һ.б.

Әйтелгәннәрдән аңлашылганча, «Хокук әсасия» китабы тел галимнәренең, аерым алганда татар телле рәсми доку-

---

[1] мәкъбуль улмышдыр – кабул ителгән; гадәткә кергән.

[2] мофрадат – аерым сүзләр.

[3] җииһәтейлә – ягы белән, ягыннан.

[4] тәркиб – сүзтезмә; сүзтезмәнең грамматик төзелеше, конструкциясе.

[5] гариб – сәер; ят.

ментлар, татар лексикологиясе һәм терминологиясе, тәрҗемә белән шөгыльләнүчеләрнең игътибарын җәлеп итәргә лаеклы.

1916 елда Муса әфәнде «***Зәкят***»[1] исемле бер хезмәтен бастыра. Китапның гонванында, ягъни титул битендә 1916 ел күрсәтелгән, гәрчә тышлыгының икенче сәхифәсенә урнаштырылган белдерүдән бу китапның 1917 елда дөнья күргән булуы ачыклана.

Китапның исеменнән үк аңлашылганча, ул ислам динендә Аллаһ рәхмәте белән кешегә насыйп ителгән малдан мохтаҗлар хакына ел саен билгеле күләмдә өлеш чыгару йоласына багышланган. Әмма китапның эчтәлеге күпкә киңрәк. Тышлыгында урнаштырылган белдерүдә Муса Җаруллаһ болай дип язган: «*Игътибар: фаъиз*[2]*, зәкят мәсьәләләрен тәфсыйляте белән бәян итеп, гаилә әсасләренә*[3] *гаъид*[4] *иҗтимагый мәсьәләләрнең мөһимнәрен хәл итмәк юлында Коръән кәрим айәт кәримәләрен, Шаригъ хәким хөкемнәрен ачык бәян итәр рисаләдер*[5]*.*

*Һәм игътина*[6]*, һәм иҗтиһад каләме белән язып, халыкның һәм әһле гыйлемнең инсаф назарларына китабымны тәкъдим иттем. Халык бу китаптан, мин әһле гыйлемнең тәнбиһләреннән*[7] *истифадә*[8] *итәрмен. То кыямәт*[9] *даъим булачак иҗтиһад мәҗлесләрендә дини, иҗтимагый, гыйльми мәсьәләләрнең һәрбере, иншаллаһ, хәл кыйлына торыр*».

Тышлыкның икенче битендә китабының эчтәлеге белән таныштыруын дәвам итеп, мондый сүзләр язган: «[китап] *ри-*

[1] Муса Җаруллаһ. Зәкят. Петроград, Типография М.– А. Максутова, 1916. 96 б.

[2] фаъиз – процент.

[3] әсас – нигез.

[4] гаъид – кагылышлы, бәйле.

[5] рисалә – язма, мәкалә, китап.

[6] игътина – бик нык дикъкать бирү; игътибарлы булу.

[7] тәнбиһ – искәртү, тәкъдим кертү; җитешсезлекләргә игътибар иттерү.

[8] истифадә – файдалану.

[9] то кыямәт – кыяматкәчә, кыяматкә кадәр.

*ба мөгамәләләре, фаъиз мәсьәләләре хакында шәригать исламия тәгълимнәрен*[1] *бәян итәр. Риба мәсьәләләрен тәмам хәл итмәк өмете белән башламыш идем, тәүфикъ*[2] *рахиләләре*[3] *үзәрендә*[4] *максат кәгъбәсенә ирештем. Ислам фәкыйһлары назарында*[5] *мөшкел* [булган]*, әһле ислам хакында иң мөһим* [булган] *мәсьәләләр, тәшәккер*[6] *лисаны*[7] *белән сөйләем, тәмам хәл кыйлынды*».

«*Зәкят*» китабы тышлыгы зәвыклы итеп үсемлекләргә тартым орнаментлар һәм шәркый стилистикада ясалган архитектур корылмалар белән бизәлеп, композиция ягыннан үзенчәлекле, шамаилләргә охшашербөтенлек тәшкил итә: анда Мәдинәдәге Пәйгамбәр мәчетенең дә, Мәккәдәге Кәгъбәнең дә сурәтләре төшерелгән, зәкяткә һәм малдан файдалануга кагылышлы берничә Коръән айәте урнаштырылган. Китапның эчтәлегенә кагылышлы татарча белешмәләр дә композициягә үрелеп кертелгән. Тышлыктагы рәсемнәрнең һәммәсе дә символик мәгънәгә ия. Коръән айәтләренең мәгънәләре исә символизмны көчәйтә генә: биредә «Бәкарә сүрәсенең» 261 нче һәм 267 нче айәтләре, «Әнфәл» сүрәсенең 41-нче һәм «Ганкабут» сүрәсенең 69 нчы айәтләре китерелгән. Моннан тыш, капка рәсеме өстендә иҗтиһад капкаларының ачык булуы турында да бер җөмлә урнаштырылган. Монысы – ислам диненең егәрен гасырлар дәвамында богаулап тоткан реакцион фикер калыплары тозагыннан коткарырга тырышучы мөҗәддидләр өчен үтә дә әһәмиятле бер дәгъвадыр.

Муса әфәнденең китап тышлыкларын бу кадәр купшы бизәү гадәте булмаган. Бу яктан «*Зәкят*»нең тышлыгы аңарчы яки соңрак чыккан китаплардан да бөтенләй үзгә. Бу Муса

[1] тәгълим – күрсәтмә бирү, өйрәтү; белем бирү.

[2] тәүфикъ – уңышка ирешү, бәхеткә ирешү.

[3] рахилә – йөк ташый торган хайван.

[4] үзәрендә – өстендә.

[5] назарында – карашында.

[6] тәшәккер – шөкер кыйлу; рәхмәт әйтү.

[7] лисан – тел.

әфәнденең әлеге әсәренә олы әһәмият бирүе белән аңлатыламы, әллә бизәүнең сәбәпләре башка булганмы – бу сорауларга җавап, бәлки, түбәндә бирелер. Башта авторның китап тышлыгында урнаштырган сүзләрен китерик: «*Мөхтәрәм әдип Госман әфәнде Акчукраклы җәнабларының кодрәт санагыясе*[1] *белән рәсем кыйлынмыш гүзәл бер зиннәт белән бу китабымның йөзен зиннәтләдем. Ислам рөкеннәре, бинасы, рухы, иҗтиһадның гайәсе*[2] *тәмам ачык тасвир кыйлынмак мәһарәте*[3] *белән, китапның иң олы максаты китапның матур йөзендә җанлы сурәте белән күрсәтелде.*

*Милләтем ихсанына*[4] *игътимад*[5] *иттем, ихсан кулы белән китапларым бәлки алыныр, ихтирам күзе белән китапларым бәлки укылыр. Башкаларының нәшеренә мин дә бәлки мәукыйф*[6] *булырмын*».

Биредә китапны бизәгән рәсемгә караган сүзләрдән ул рәсемгә салынган мәгънә дә аңлашыла булса кирәк. Игътибарны җәлеп иткән тагын бер нәрсә – авторның «милләтем» сүзен куллануы. Муса әфәнденең бу сүзне башка бер китабында кулланганын очратканым юк. Димәк, авторның туган халкына шул кадәр сөеп дәшүендә, бу кадәр самими һәм үтемле сүз куллануында ниндидер тирән мәгънә ятарга тиеш. Бу мәгънә, миңа калса, китапның эчтәлегеннән аңлашыла. Монысы гаҗәп, чөнки зәкят, иман ияләренә, ягъни хәерле бәндәләргә йөкләнелүенә карамастан, шактый коры бер икътисади төшенчә булып кала. Ул хисләнүләргә, күңел нечкәрүләренә урын калдырмый кебек. Әмма Муса әфәнденең әлеге төшенчәне аңлавы үзгә: гыйльми эшчәнлегенең тарихка караган юнәлешләрендә ул ислам дөньясының үткәнен һәм хәзергесен өйрәнү белән генә чикләнмичә, мөселманнарның артта калула-

---

[1] кодрәт санагыя – сәнгати көч, сәләт.

[2] гайә – максат.

[3] мәһарәт – осталык.

[4] ихсан – киң күңеллелек; игелеклелек, мәрхәмәтлелек.

[5] игътимад – таяну.

[6] мәукыйф – ирешүче, булдыручы.

рының, нык алгарыш кичергән Гареб[1] илләре вә милләтләренең бер мескен фәкыйрь колы хәленә төшүенең сәбәпләрен дә ачыклаган. Халкына карата иң изге хәерхаһ теләкләрдә булган Муса әфәнде, әлбәттә, аны да, гомумән, мөселман өммәтен дә бу бөлгенлектән, артта калганлыктан, хурлыклы коллык һәм әсирлектән коткаруны үзе өчен максат итеп куйган. Котылу юлларын ул үзенең дини китапларында да бәян иткән, иҗтимагый һәм сәяси эшчәнлегендә дә алгы планга куйган.

«***Зәкят***» китабында да нәкъ әнә шундый мотивлар урын ала. Муса әфәнденең карашынча, мөселманнарны тарихның сукыр тыкрыгыннан чыгаруда иман да, әхлак та, фикъһы һәм башка дини гыйлемнәр дә, мәгариф системасы да, тәрбия дә, хатын-кыз да, гаилә дә, фән-технологияләр дә – һәммәсе әһәмиятле. Боларның берсенә генә басым ясап, башкаларын һич тә читкә куярга ярамый – һәммәсен бергәлектә, таркатылмый торган бербөтенлек буларак игътибар үзәгендә тотарга, эзлекле сурәттә үстерергә кирәк булуын Муса әфәнде бик яхшы аңлаган. Зәкят белән дә шулай. Әлбәттә, ислам дөньясын куәтле һәм мөстәкыйль көч буларак цивилизация мәйданына яңадан чыгару чараларын барлаган һәм өммәткә тәкъдим иткән Муса әфәнде икътисадка игътибар итмәсә – ул Муса Бигиев булмас иде дә. Зәкят турындагы китабында Муса әфәнде хәзерге заманыбызда да «ислам икътисады» буларак һаман да игътибар үзәгендә торган тәгълиматка – шәригатьнең катгый хөкемнәренә таянган теориясе һәм практикасына нигез салырга омтылыш ясаган. Шуңа күрә бу китапта банк проценты (фаъиз), риба кебек мәсьәләләрнең каралуы табигый. Муса әфәнде китабының беренче битләрендә үк мәсьәләне кискен сурәттә укучының хөкеменә тәкъдим итә: «*Җир, сәүдә, сәнәгать налогларын зәяттән хисаб итү мөмкинме? Әгәр дә мөмкин түгел исә, сәүдәгәрләр, игенчеләр хакында зәкят кебек, гошер кебек фарызлар золым булмасмы?» дигән сораулар 1915 ел ноябрьнең 15 ендә чыккан 22 номер «Шура»да, 702 нче сәхифәдә куелганнар иде. Бу мәсьәлә матбугат*

[1] Гареб – тарихи-мәдәни төшенчә буларак,күмәк Көнбатыш. Гареб сүзеннән тыш Муса әфәнде әсәрләрендә шул ук мәгънәгә ия булган Мәдәният дөньясы дигән гыйбарәне дә кулланган.

*сәхифәләрендә яңа булса да, халык фикерендә, сәүдәгәрләр авызында иске бер мәсьәлә булса кирәк*».

Әлбәттә, мондый өстәмә дини салымнар исламга карата тискәре мөнәсәбәт уятырга мөмкин. Муса әфәнде проблеманың никадәр әһәмиятле һәм киеренке булуын аңлап, аны чишүгә таба хәрәкәт итә, әмма сүзен ерактан башлый. Аның әйтүенчә, ислам дөньясының икътисади зәгыйфьлеге фәкыйһларның дин хөкемнәрен дөрес аңлатмауларына барып тоташа. Бу хәл колониаль изү дәверендә үзен аеруча нык сиздерә башлый. Муса әфәнде заманына кадәр инде ике-өч гасыр дәвамында изелгән колонияләр хәлендә көн күргән мөселман илләре ике мәҗбүрият арасында кала: бер яктан, Көнбатышның икътисади калыпларына яраклашу мәҗбүрияте, икенче яктан, шәригать буларак, фәкыйһлар тарафыннан рөхсәт ителгән гаять тар һәм бик сай икътисади алымнарны куллану мәҗбүрияте.

Бу драматик каршылыкны хәл итү өчен Муса әфәнде ислам динендәге икътисади категорияләрне яңабаштан анализларга, аларны яңача аңларга чакыра һәм, беренче нәүбәттә, хәлал риба белән хәрам риба кебек төшенчәләрне булдырып, аларны бер-берсеннән аерырга тәкъдим итә. Ягъни, кыен хәлдә калган яки бәлагә дучар булган кешенең котылгысыз хәлдә калуыннан матди файда күрү – аңа кредит биреп, әҗәткә алынган акчаны арттырып кире түләтү – классик мәгънәдә хәрам риба булып кала. Мондый рибаны дин күзлегеннән дә, әхлак күзлегеннән дә кабул итү мөмкин дә, тиеш тә түгел. Әмма сәүдә, җитештерү һәм, гомумән, керем алыначагы күздә тотылган башка максатлар өчен бирелгән кредиттан фаъиз (процент) алу – Коръәндә тыелган риба хөкемендә булмый, чөнки биредә сүз икътисади иптәшлек, үзара килешүгә корылган һәм уртак булган керем алуны максат итеп куйган икътисади партнерлык турында бара.

Аңлашылганча, Муса әфәнденең «*Зәкят*» исемле китабы әле бүген дә үзенең әһәмиятен югалтмаган һәм ул икътисад белән шөгыльләнүче мөселманнарның – фәкыйһлар булсын, эшмәкәрләр булсын – һәммәсе өчен дә файдалы була ала.

1916 елга караган тагын бер кызыклы мәгълүмат белән уртаклашасы килә. Әле 1915 елда ук бөек рус язучысы, яшь чагында Казанда яшәп, соңыннан бу шәһәрне үзенең тормыш университетлары дип олылаган Максим Горький[1], мәгърифәтче әдип буларак, рус халкын Русия хакимияте астында яшәгән халыклар белән таныштыруны күздә тоткан масштаблы бер мәдәни-әдәби проект башлаган. Нияте – үз эченә милли әдәбиятлар үрнәкләрен һәм милли тарих сәхифәләрен алган җыентыклар әзерләп бастыру һәм тарату була. Шулай итеп, украиннарга, финнарга, әрмәннәргә һәм грузиннарга багышланган китаплар әзерләнә башлый. Шул ук силсиләгә кергән «Российские мусульмане» исемле җыентык әзерләүне Горький Зәки Вәлидигә тапшыра. Вәлиди, Русия мөселманнары турында бик күп мәгълүмат җыеп, чын мәгънәдә фәнни эш башкарып чыга һәм 1916 елның язында бу хезмәтенең кульязмасын тәмамлый. Әзер кульязманы укып чыккан Горький аңа тирән эчтәлекле яхшы кереш сүзе яза. Кульязманы укыган чагында Горький Муса Җаруллаһның да анда бәян ителгән фикерләре һәм фәлсәфи карашлары белән таныша. Җаруллаһның фикер дөньясына тәэсир иткән рус һәм Аурупа галимнәре белән беррәттән, Зәки Вәлиди кульязмасында, Урта гасырларда ук дан казанган олуг мөселман фикер ияләрен дә искә алып, аларның Муса әфәнде өчен рухи азык һәм гыйлем чыганагы булуларын ассызыклаган була. Моны күргәч Максим Горький исе китеп: «Мин татарларның мәдәни бәйләнешләренең бу кадәр тирән һәм киң булуын һич күз алдыма китермәгән идем»,– дигән[2].

[1] Максим Горький (Алексей Максимович Пешков; 1868–1936) – рус совет язучысы, шагыйрь, драматург, журналист, публицист һәм җәмәгать эшлеклесе.

[2] Тоган. Воспоминания. Т. 1. Б. 167.

# Өченче фасыл.
# 1917–1930 еллар: Совет хакимияте астында

## Февраль инкыйлабыннан соң

1917 елда Россия империясе, ике инкыйлаб аша узып, упкынга таба чираттагы адымнарын ясый. Әмма Февраль буржуаз-демократик инкыйлабын Муса әфәнде шатланып кабул итә. Бу турыда «Исляхат әсасләре» исемле китапның 1917 елның март аенда чыккан яңа тиражында урнаштырылган сүзләрдән укып белә алабыз: «...*Бу игътизарым*[1] *әсирлек төннәренең соңгы дакыйкаларында, соңгы караңгылыкларында язылды. Февраль ахырларында, март башларында хөррият кояшы игътидаль*[2] *ноктасына иреште, гаделлек язы, тигезлек нурлары белән халыкның күңелләрендә шатлык гөлләрен үстерде. Русиядә гаять зур инкыйлаб тәмам җиңеллек белән чынбарлыкка ашты*».

Муса әфәндене Русиядә хөррият һәм гаделлеккә юл ачылуы гына түгел, сәяси-иҗтимагый яссылыкта ил күләмендә барган зур принципиаль үзгәрешләрнең ислам диненә дә, мөселманнарның тормышларына да бәрәкәтле тәэсир итү перспективалары өметләндерә һәм канатландыра. Мәсәлән, шул ук 1917 елда дөнья күргән «***Шәригать әсасләре***»[3] исемле китабында бу турыда Муса әфәнде болай дип язган: «*Бу китабымны әүвәлге шәригатьләр, мәдәни кануннар арасында ислам шәригатенең үзәген тәгаен итү теләге белән дә язган идем. Әсирлек төннәренең соңгы минутларында тәмамла-*

[1] игътизар – гафу үтенү.

[2] игътидаль – күк җисемнәренең, җирле меридиан аша (зенит) үтеп, күк йөзендә иң югары ноктага ирешүләре.

[3] Муса Җаруллаһ. Шәригать әсасләре. Петроград: Типография М-А. Максутова, 1917. 74 б.

*нып, бөек инкыйлабның әүвәлге сәгатьләрендә китап базарына чыкты.*

*Әлеге сәер хәл минем өметемне нурландырды: әлбәттә, бу бөек инкыйлаб Русия чикләрендә генә калмас, бәлки бөтен җир йөзенә таралыр. Хәзерге сәяси инкыйлаб моннан соң гаять бөек иҗтимагый инкыйлабның да бисмилласы булыр; һәр җирдә хокук, тәртип, канун тәмам алыштырылганнан соң, әлбәттә, ислам фикъһысы бүгенге хәлендә калмас; бәлки, ислам шәригате бөтен камиллеге белән, Коръән кәриме белән, Сөннәт нәбәвиясе белән мәдәният дөньясына чыгар; ислам галәменең иҗтимагый вазгыяте, сәяси дәрәҗәсе исламият куәте белән ислях кыйлыныр; диннәр арасында исламиятнең абруена туры килгән сәяси дәрәҗә вә гыйззәт мөселманнар шәрәфенә, әлбәттә, тәэмин ителер, дидем.*

*Бу кечкенә китабымда ачык тел белән әйтелгән уй-фикерләрем бу зур өметнең юлларын ачарга тиеш иде. Шуңа күрә, шатландым, өметем куәтләнде, ислам фикъһысында бөек инкыйлаб көннәрен күргән кебек булдым*...»[1].

Чыннан да, инкыйлаб тәэсире белән Муса әфәнденең киләчәккә караган өметләре зур була. Әмма 1917 ел вакыйгалары ил язмышын гына түгел, анда гомер кичергән халыкларның да, һәр аерым шәхеснең, хәтта кешелек цивилизациясенең язмышын да дәһшәтле кискен үзгәрешләргә дучар итә. Муса әфәнде үзе дә, аның гаиләсе дә бу туфаннардан, әлбәттә, читтә кала алмыйлар. Шулай итеп, 1917 елдан башлап, аның тормышы шатлыклы һәм кайгылы вакыйгаларга бай булган яңа дәверенә керә. Русия мөселманнарының сәяси фәгалиятләре дә кисәк кенә җанланып-көчәеп китә. Сәяси бәрелешләр үзәгенә әйләнгән Петроградта гомер кичергән актив мөселманнар, аерым алганда, IV Дәүләт думасының мөселман фракциясе вәкилләре, Думада депутат булмаса да – Муса әфәнде, диндәшләрнең бердәм булуының әһәмиятлелеген аңлап, җиң сызганып эшкә тотыналар.

Ул көннәрдә Петроград мөселманнарының активында яңа мөселман корылтае үткәрү идеясе күтәрелә һәм бу зур чара-

[1] Хәзерге татар теленә тәрҗемә.

ны әзерләү һәм үткәрү максаты белән март аенда башкалада «Русия мөселманнарының вакытлы мәркәз бюросы» исемле оешма төзелә. Бу вакытлы оешманың рәисе итеп Әхмәт Цаликов[1] билгеләнә, Садри Максуди, Әхмәт-Зәки Вәлиди, Ильяс Алкин[2], Шакир Мөхәммәдъяров[3] кебек шәхесләр белән бергә, Муса әфәнде дә оешманың башкарма шурасы әгъзасы ителә. Бу кешеләр корылтай үткәрү өчен әзерлек эшләрен башлыйлар: чарада катнашу шартларын, аның программасын әзерләп-бастырып чыгаралар, Корылтайга әзерләнү мәшәкатьләре белән бергә, бюрода халыкны кызу үзгәрешләр дәрьясында хәбәрле итү һәм аның сәяси активлыгына дөрес юнәлеш бирү өчен, татар телендә бюро исеменнән «Хәбәрләр» исемле газета чыгара башлау карала, мөфти хәзрәт Баязитовны урыныннан алып, аның урынына мөселманнар тарафыннан сайланылачак вакытлы комиссар кую идеясе алга сөрелә. Вакытлы мәркәз бюро (ВМБ) әгъзалары, «Известия Временного центрального бюро российских мусульман» исемле гәзитнең апрель аенда чыккан беренче санында күтәренке рухта язылып, Русиянең барлык мөселманнарына аталган «*Мөрәҗәгать*» бастырып чыгаралар: «*Рухнули стены вековой темницы. Вот они наступили, наконец, светлые дни всероссийской свободы.*

*Сколько кровавых жертв было принесено к подножью царского трона, прежде чем взошло над измученной страной солнце свободы. Могучим ударом революционный народ опрокинул подгнившее здание. За нами мрачное прошлое,*

[1] Әхмәт Цаликов (Тембулат углы Әхмәт Цаликов; 1882–1928) – осетияле язучы, публицист, тарихчы, журналист, 1921 елда Аурупага күчеп китә.

[2] Ильяс Алкин (Сәет-Гәрәй углы Ильяс Алкин; 1895–1937) – җәмәгать һәм сәясәт эшлеклесе, 1917 ел Февраль революциясеннән соң Хәрби шура рәисе, шул ук вакытта Милли шура рәисе; географ, Бөтенрусия Учредительное собрание әгъзасы.

[3] Шакир Мөхәммәдъяров (Зариф углы Шакир Мөхәммәдъяров; 1883–1967) – җәмәгать һәм сәясәт эшлеклесе, хокукчы-юрист, публицист, педагог; Бөтенрусия мөселманнарының милли шурасы әгъзасы.

*впереди – светлые зори возрождения. Крик восторга и ликования несется из нашей груди – мы свободные граждане свободной страны. Где-то в далеком прошлом теряются долгие годы позора, унижений, рабства, двойного рабства, как подданных царя и как мусульман… В братском единении с другими народами России мы стоим теперь перед огромными задачами государственного строительства. Нам нужно воздвигнуть величественное государственное здание, и это здание должно быть воплощением лозунга свободы, равенства и братства народов. Какой колоссальный труд, какая беспримерная задача, и как слабы наши силы. Напряжем же все наши усилия, всю энергию, весь мозг. Будем же работать, не покладая рук. Вот когда время проявить всю глубину нашей любви к народу, всю скорбь за его прошлые обиды и оскорбления. Нас, мусульман, миллионы, но как слабо звучит наш голос в стране, как ничтожен наш удельный политический вес. Но наступило время и для нас занять в стране то место, которое принадлежит нам по праву нашего количества. Всеобщее, прямое, равное и тайное избирательное право в учреждения местные и общегосударственные, возвещенные новым правительством, должно явиться орудием нашего влияния на судьбы страны. Было бы безгранично позорно, если бы мы не сумели воспользоваться этим могучим орудием. Но воспользоваться им мы можем только при одном условии – немедленной интенсивной организации наших сил.*

*Наш лозунг: Граждане-мусульмане, организуйтесь! Мы, мусульмане, в подавляющем большинстве представляем из себя тот средний общественный слой, который носит название демократии. У нас ничтожное количество представителей капитала и представителей крупного землевладения; наш пролетариат только что стал образовываться. Классовая дифференциация в мусульманской среде слаба. В этом наш плюс и в этом наш минус. Классовая дифференциация ведет к интенсивной политической жизни – и в этом ее плюс, но она ослабляет общий напор нации – в этом ее минус. Ослабим же минус и усилим плюс. За организацию, мусульмане!*

*Наше знамя – знамя демократии. Только полное и последовательное торжество демократии гарантирует нам полноту национально-культурного самоопределения. Под знаменем демократии нам и нужно организоваться. Нужно на местах создавать демократические мусульманские народные комитеты. Объединять эти комитеты в областные союзы… Покрыть сетью таких комитетов все населяемые нами места и создать могучий союз мусульманской демократии. Областные, уездные и городские народные мусульманские комитеты должны приняться немедленно за интенсивную работу. Выпуск листков, брошюр, устройство митингов, лекций, организации профессиональные, кооперативы и т.п.– все формы организации, пропаганды и агитации должны войти в непосредственные задачи этих комитетов…*

*Дабы столковаться, выработать общие лозунги – мы ставим на очередь дня Всероссийский мусульманский съезд.*

*Безграничное поле работы. Нельзя терять ни одной минуты… Нужно помнить, что от интенсивности этой работы зависят наши исторические судьбы. За работу, граждане-мусульмане. Будем же стоять на высоте великих исторических дней. Будем же достойны свободы… Заря возрождения высоко подымается над нашими головами… Да вольет ее лучезарный свет энергию в нашу грудь, да вдохновит наши сердца.*

*Да здравствует свободная Россия свободных народов!..*

*Да здравствует свободный мусульманский мир!..*»

Урыс телендәге әлеге документның ялкынлы стилистикасы һәм купшы сурәтләү чаралары аның, һичшиксез, Муса әфәнденең тәҗрибәле каләме белән язылган булуына ишарә итә.

Әлеге мөрәҗәгатькә салынган ташып торган егәр беренче булып диярлек мөслимәләрне, ягъни мөселман хатын-кызларын уята. Аның нәшер ителүе белән – 1917 елның инде март аеның 5 есендә – Мәскәүдә яшәүче мөселман ханымнар Дәүләт думасының мөселман фракциясе вәкилләренә Казанда Бөтенрусия мөселман хатын-кызлары корылтае үткәрү ту-

рындагы тәкъдимнәрен җиткерәләр. Тәкъдим кабул ителә һәм 24 апрельдә Казанда I Бөтенрусия мөслимәләр корылтае ачыла. Чарага килгән 71 делегат һәм 300 кунак арасында Муса әфәнде дә була. Биредә ул исламда хатын-кыз мәсьәләләренә багышланган чыгыш ясый.

Әлеге корылтайда Муса әфәнденең чыгышы буш урында килеп чыккан нәрсә түгел. Хатын-кыз мәсьәләсе – аның тарафыннан инде күптән алып барган гыйльми тикшеренүләренең үзәгендә торган проблемаларның берсе. Моның шулай булуы 1917 елда чыккан «*Шәригать әсасләре*» исемле китабында язганнарыннан аңлашыла:

«*Дөнья сугышы елларының ахырында, 1916 нчы елның азакларында бөек инкыйлабларның сәхәрендә*[1] *нәшер кыйлынган «Шәригать әсасләре» исемле китапның 40 нчы сәхифәләрендә хатын-кызларның хокуклары хакында бу сүзләрем бар иде:*

*«Илаһилек хозурында пакь вә гөнаһсыз булган Мәрьям Аллаһ җәллә җәлалүһу хәзрәтләренең гади бер әммәседер*[2]. *Бер әммәгә карата Коръән кәрим шулкадәр игътибар вә әһәмият белдергән исә, аны шулкадәр югары әдәп үрнәге буларак күрсәткән исә, хатын-кызларның һәрбере хакында кайгырту, хатын-кызларның хөрмәтләрен, хокукларын һәрвакыт һәрьяклап саклау фәкыйһләрнең һәрберенә, һәйәт иҗтимагыя*[3] *әгъзаларының һәрберенә, әлбәттә, тиеш булыр, вазифа булыр*».

«*Мәдәни, иҗтимагый, сәяси, дини, әдәби хокукларның һәрберен хатын-кызларның һәрберенә ислам шәригате тулысынча камил сурәттә тапшырган. Минем игътикадым будыр. Хакыйкать будыр. Мөһим хокукларның кайберләреннән хатын-кызлар, ислам фәкыйһләре карашында, мәхрүм булсалар да, бүген мәдәният мәркәзләрендә*[4] *хокукларның иң*

[1] сәхәр – таң атар алдыннан була торган караңгылык.

[2] әммә – бәндә, колиһә.

[3] һәйәт иҗтимагыя – җәмгыять төзелеше; иҗтимагый система.

[4] мәдәният мәркәзләре – югары дәрәҗәдәге мәдәнилекне дәгъва кыйлган Көнбатыш илләре күздә тотыла.

*мөһимнәре хатын-кызларның карамагына тапшырылмаган булса да, хокукларның һәрберен хатын-кызларның карамагына ислам шәригате тулысынча тапшырды».*

*«Бу бөек һәм таләп ителгән хакыйкатьне исламият хөрмәте белән, Коръән кәримнең ярдәме белән Аллаһ җәллә җәлалүһу хәзрәтләренең булышлыгы белән көннәрнең берсендә, иншәэ Аллаһ, исбат итәрмен».* (لَا أَبْرَحُ حَتَّى أَبْلُغَ مَجْمَعَ الْبَحْرَيْنِ أَوْ أَمْضِيَ حُقُبًا)[1] *мондый бөек дәгъваларга мин һәрвакыт батырчылык итәм, кодрәтем, куәтем этәрүе белән түгел, бәлки гыйшкым кушуы белән», – дигән идем.*

*Бу сәхифәләр ул вәгъдәләрне үтәү булсын.*

*Кешелек дөньясының кямил бер яртысы булу, гаиләләрнең иң мөһим терәге булу шәрәфләренә өстәмә буларак, Коръән кәримдә* (حَمَلَتْهُ أُمُّهُ وَهْنًا عَلَى وَهْنٍ وَفِصَالُهُ فِي عَامَيْنِ)[2] *(31:14);* (حَمَلَتْهُ أُمُّهُ كُرْهًا وَوَضَعَتْهُ كُرْهًا وَحَمْلُهُ وَفِصَالُهُ ثَلَاثُونَ شَهْرً)[3] *(46:15);* (وَالْوَالِدَاتُ يُرْضِعْنَ أَوْلَادَهُنَّ حَوْلَيْنِ كَامِلَيْنِ)[4] *(2:233) кебек аятә кәримәләрдә искә алынган вазифалары турында да фикер йөртсәк,* (وَلَهُنَّ مِثْلُ الَّذِي عَلَيْهِنَّ بِالْمَعْرُوفِ)[5] *дигән аятә кәримә даирәсеннән дә тышта торган хокук табыла алырмы?*

*Әлбәттә, юк, табылмас. Коръән кәрим хатын-кызларны ихтирам итә. Көнбатыш милләтләренең ихтирамнары белән чагыштырылмас дәрәҗәдә, Шаригъ хәким, галәйһис-саләт вә-с-сәлам, хәзрәтләре хатын-кызларны ихтирам итә иде. Феминистлар кебек, бары тик тән рәхәте, гүзәллек куәте белән түгел иде, бәлки изгелеккә ия булган вазифаларын, бөек әһәмиятләрен тану һәм кадерләү юлы белән иде.*

---

[1] «Мин ике диңгезнең кушылган урынына барып җитмичә туктамаячакмын, мәгәр еллар үтсә дә» («Тау Куышы», 18:60).

[2] «анасы аны кыенлык өстенә кыенлык күреп карынында йөртә, аны имидән аеру ике яшенә җиткәчтер» («Локман», 31:14).

[3] «Анасы аны җәфа чигеп карынында йөртте һәм җәфа чигеп тудырды. Аны карында йөртү белән имидән аеру (һәммәсе бергә) утыз алты айдыр» («Комнар», 46:15).

[4] «Бала тудыручылар үзләренең балаларын тулы ике ел буе имезәләр» («Сыер», 2:233).

[5] «Гадәт буенча, аларның өстендә булган вазифаларына тиң хаклары да бар» («Сыер», 2:228).

*Кадим вә җәдид бөтен диннәргә нисбәтән исламиятнең бөек ике аермасы бар: 1) мәгъбүдне[1] тәүхид[2], 2) хатын-кызларны кадерләү. Кадерләүнең гаять бөек бер шаһиты* (وَلَهُنَّ مِثْلُ الَّذِي عَلَيْهِنَّ بِالْمَعْرُوفِ)[3] *дигән канундыр: «тиңдәшсез вазифаларына тәңгәл була алачак хокукларны да хатын-кызларга бирегез», – дип әйтү: «булдыра алганыгыз кадәр хатын-кызларны ихтирам итегез», – димәктер.*

*Коръән кәрим хатын-кызларның хәтта каннарыны да изгеләштерә: нәселнең дәвамына хезмәт итүе шәрәфе белән, хәезнең[4] һәм нифасның[5] һәр минуты, намаз кебек, бөек гыйбадәт булып санала; ул дакыйкаларда ханымнарга намаз уку фарыз булмый. Бу минутларда илаһилек хозурларына хатын-кызларның тагын да якын булулары шәрәфе белән һәр минутлары намаз кебек була.* (فَاعْتَزِلُواْ النِّسَاء فِي الْمَحِيضِ)[6] *кебек тыйбби[7], саулыкка кагылышлы күрсәтмәләре арасында изгелеккә ия булган бер хикмәте дә будыр. Кан көннәрендә хатын-кызларның изгелекләре артса да, канның табигый үзенчәлеге дә бар. Кан көннәренең ахырында, шуңа күрә, госел алу, тыйбби бер күрсәтмә буларак, әмер ителгән. Андый көннәрдә хатыннардан читләшү һичкайчан ваҗиб булмаса да, ханымнарны ялгыз калдыру турындагы әмерне тәмамлау өчен алар госелләнгәннән соң шуңа күрә,* (فَأْتُوهُنَّ مِنْ حَيْثُ أَمَرَكُمُ اللّهُ)[8] *дигән әмер иңдерелгән. Аят кәримә ахырында шуңа күрә* (إِنَّ اللّهَ يُحِبُّ التَّوَّابِينَ وَيُحِبُّ الْمُتَطَهِّرِينَ)[9] *дигән сүзләр сайланылып; Ал-*

---

[1] мәгъбүд – табыныла торган нәрсә; ислам динендә мәгъбүд – Аллаһ.

[2] тәүхид – берләштерү; Аллаһның бердән-бер булуын тану.

[3] «Гадәт буенча, аларның өстендә булган вазифаларына тиң хаклары да бар» («Сыер», 2:228).

[4] хәез – күрем.

[5] нифас – бала тапканнан соң була торган канау.

[6] «Күрем вакытында ханымнардан читләшеп торыгыз» («Сыер», 2:222).

[7] тыйбби – сәламәтлек саклауга караган; медицинага караган.

[8] «сезгә Аллаһ боерганча алар янына килегез» (Коръән, 2:222).

[9] «Дөреслектә, Аллаһ тәүбә итүчеләрне һәм пакьләнүчеләрне сөя» (Коръән, 2:222).

*лаһның яраткан нәрсәләренең икесе дә аерым-аерым ир-атны белдергән сүз шәкелендә китерелгән. Ягъни ханымнар таһирдыр, хәез, нифас бәрәкәте белән аларның гөнаһлары калмаган. Хатыннарын калдырып торганнары өчен ирләрнең тәүбәләрен, хатыннары белән якынлык кыйлу бәрәкәте белән ирләрнең тәһарәтләнүләрен дә Аллаһ, җәллә җәлалүһу, хәзрәтләре әмер итә. Болар барысы да хатын-кызларның хөрмәте хакында, нәселнең бөек әһәмияте хосусында Коръән кәримнең гаҗәеп һәм саф кайгыртуыдыр. Юкса, Аллаһ Коръән кәримдә* (ان الله يحب التوابين ويحب المتطهرات)[1] *дип әйтә алыр иде*»[2].

Гомумән, Муса әфәнденең мирасында хатын-кыз темасының ислам дине тарихында һәм дини фикер тарихында аңарчы күрелмәгән дәрәҗәдә диярлек югары күтәрелүен әйтеп узарга кирәк. Галим бу җитди проблемага багышланган фикер вә карашларын байтак әсәрләрендә яңгырата, аны комплекслы сурәттә, диннең рухына һәм шәригать таләпләренә туры китереп хәл итү юлларын күрсәтә. Андый әсәрләре арасында 1916 елда ук тәмамланып та, бары тик 1933 елда Берлинда дөнья күрә алган «*Коръән кәрим айәт кәримәләре нурлары хозурында хатын*» исемле бәһасез әсәрен искә алырга кирәк. Муса әфәнденең бу китабында хатын-кыз мәсьәләсенә карата бәян иткәннәренә алга таба игътибар итәрбез.

## Мәскәү: I Бөтенрусия мөселман корылтае

1917 елның 1–11 маенда Мәскәүдә Әсадуллаев[3] йортында чираттагы V Бөтенрусия мөселман корылтае үткәрелә. Русия мөселманнарының 1914нче елда узган IV съездында нибары берничә дистә делегат катнашуын истә тотканда, бу корыл-

---

[1] тәрҗемәсе: «Дөреслектә, Аллаһ таһәрәтләнүче (ханымнарны) һәм тәүбә кыйлучы (ирләрне) сөя».

[2] Өзек хәзерге татар теленә тәрҗемә ителде.

[3] Әсадуллаев (Шәмси Әсадуллаев; 1840/41–1913) – азәрбайҗанлы нефть җитештерүче сәнәгатьче, миллионер, фән һәм сәнгатьпәрвәр кеше, хәйрияче. Мәскәүдә мөселманнарның мәнфәгатьләре өчен «Әсадуллаев йорты» дип аталган аерым йорт салдырып, диндәшләренә вакыф кылган кеше.

тай эшендә 900 делегат катнашуы, беренчедән, Муса әфәнде әгъзалык иткән Вакытлы мәркәз бюро исеменнән таратылган (һәм, мөгаен, аның кулы белән язылган) Мөрәҗәгатьнең гаять тәэсирле булуын раслый, икенчедән, корылтайны әзерләү юнәлешендә ВМБ әгъзалары башкарып чыккан эшләрнең нәтиҗәле булуын ассызыклый һәм, өченчедән, Русия мөселманнарының илдә барган демократик үзгәрешләргә никадәр зур өметләр баглауларын, сәяси-иҗтимагый эшчәнлектә катнашырга никадәр зур теләктә булуларын күрсәтә. Делегатлар арасында йөздән ике йөзгә кадәр хатын-кызның булуы исә Русиядәге исламның алга таба никадәр тирән һәм уңай үзгәрешләр кичерергә әзер булуына ишарә итә.

Корылтай Коръән айәтләрен уку белән ачыла һәм Муса әфәнденең чыгышы белән эшен башлап җибәрә. Эшнең башында ук Муса әфәнде унике кешедән торган президиумга сайлана. Мөселманнарның бу җыенында Русия дәүләтенең эчке төзелеше, Учредительное собраниегә сайлау кампаниясендә катнашу алымнары һәм тәртибе, җирле үзидарә, аграр, эш, милли мәгариф, хатын-кыз, сугыш һәм хәрби оешмалар, дин кебек үтә дә җитди мәсьәләләр карала. Муса әфәнде исламда хатын-кыз хокуклары турында доклад ясый. Аның чыгышы кызу бәхәсләр кузгата; каршы чыгучыларның күбесе Төркестан делегатлары була, чөнки алар гомумән хатын-кызны дини-иҗтимагый яшәешнең бер субъекты буларак танырга һәм аның турында җитди сүз йөртелүенә бөтенләй әзер булмыйлар. Шулай да, Муса әфәнденең хатын-кыз мәсьәләсен хәл итү чараларын тәкъдим иткән чыгышы 10 маддәлек документ хәленә китерелеп, тавышларның күпчелеге белән кабул ителә.

Дин мәсьәләләренә килгәндә, корылтай моңарчы тарихта мисалы булмаган адымнар ясый. Беренчедән, Русия ислам җәмәгатьчелеге мөфтине беренче мәртәбә үз иреге белән сайлый. Мөфтилеккә тәкъдим ителгән биш кандидат арасында Муса хәзрәт тә була[1]. Сайлау нәтиҗәсендә мөфтилекне Га-

[1] Калган дүрт кандидат: Галимҗан Баруди, Габдулла Буби, Хәсән-Гата Габәши һәм Садри Максуди булалар.

лимҗан хәзрәт Баруди казана. Икенчедән, корылтайда Диния нәзарәтенә бөтендөнья ислам тарихында беренче мәртәбә шәригать хакиме (судьясы) итеп казый түгел, ә казыя, ягъни хатын-кыз сайлана. Бу мәртәбәле постны мөселманнар танылган мөгаллимә, милли мәгарифнең якты йодызы Мөхлисә ханым Бубыйга ышанып тапшыралар.

Корылтайның ахырына таба, мөселманнарның сәяси, иҗтимагый, икътисади, мәдәни, дини яшәешләрен тәрәккыять юнәлешендә үстерү өчен һәм мөселманнар исеменнән дәүләт органнарында вәкиллек кылу өчен, Корылтайда утыз әгъзадан торган Бөтенрусия мөселман шурасы – Милли шура – сайлана. Ул утыз кеше арасында Эчке Русия һәм Себердән 10 вәкил (А. Цаликов, Ф. Кәрими, И. Әхтәмов, З. Шамил, М. Бигиев, И. Алкин, М. Төмәнов, Ш. Мөхәммәдъяров, С. Максуди, Г. Исхакый), Төркестан, Харәзем һәм Бохарадан – 7, Казакъстаннан – 5, Кырымнан – 2, Кавказдан – 5 һәм Литва татарларыннан 1 вәкил була. Үз нәүбәтендә Милли Шура составыннан А. Цаликов җитәкчелегендә эшлисе унбер кешедән гыйбарәт булган Башкарма һәйәте (комитеты) (МШБК) тәгаенләнә. Муса әфәнде белән бергә бу органга И. Алкин, Ибраһим һәм Ибнейәмин Әхтәмовлар, Ш. Мөхәммәдъяров, С. Максуди, Г. Исхакый, И. Леманов, Ә.-З. Вәлиди, М. Төмәнов кебек шәхесләр сайлана.

Әлеге орган исеменнән Вакытлы хөкүмәткә (Временное правительство) юлланылган рәсми хатта Вакытлы хөкүмәт тарафыннан Бөтенрусия мөселман шурасын, ягъни Милли шураны Русия мөселман җәмәгатьчелегенең бердәнбер вәкаләтле сәяси үзәге буларак танылуы һәм мөселманнарга кагылышлы мәсьәләләрдә бары тик Милли шура белән хезмәттәшлек ителүе соралган була. Җәмәгатьчелек белән элемтәдә торыр өчен Милли шура «Известия Всероссийского мусульманского совета» исемле гәзит оештыра. Гәзитнең беренче саны июньнең 30-ында чыга, соңгы саны 1918 елның 11 гыйнварында дөнья күрә. Шулай ук 1917 елның май аенда үткәрелгән җыенны V нче итеп түгел, ә I Бөтенрусия мөселман корылтае буларак теркәү карар кылына. Җыен

эшенең соңгы көнендә чираттагы корылтайларның үткәрелү урыннары билгеләнә: II нче корылтайны Казанда, III-нчесен Ташкентта, IV-нчесен Бакуда үткәрү планлаштырыла.

Милли шураның 1917 елның 13 маенда үткәрелгән 2 нче утырышында кабул ителгән карар нигезендә, Муса әфәнде 1917 елда үткәрелгән I Бөтенрусия мөселман корылтае протоколларын рус һәм татар телләрендә бастырып чыгару өчен оештырылган Махсус мөхәррирлек һәйәтенең әгъзасы ителә[1]. Майның 22-сендә үткәрелгән 3 нче утырышта Милли шурада Харәзем[2] ханы Әсфәндиярның[3] һәм ханлыктан килгән делегатларның үтенече карала. Сүз Харәзем мөселманнары тормышын конституциягә туры килгән яңа шәкелгә салып үзгәртеп кору өчен, бу эшне башкарып чыгарлык белгечләрдән торган махсус комиссия җибәрелүен сорап, Милли шурага мөрәҗәгать итүләре турында бара. Озак кына фикер алышканнан соң, Харәземгә баш дин белгече буларак Муса хәзрәтне һәм аның белән бергә бер финансчы һәм бер юристны командировкага җибәрү турында карар кабул ителә[4]. Харәземдә Муса әфәнде җирле рухани оешмаларны һәм мәгариф оешмаларын (мәктәпләрне) оештыру белән шөгыльләнергә тиеш була.

Шул ук 1917 елда Казанда Муса әфәнде төзегән «***1917 ел 1–11 майда Москва шәһәрендә гомум Русия мөселман съезды хакында кыскача мәгълүмат***»[5] исемле документлар җыентыгы басылып чыга.

---

[1] Бөтенрусия мөселман шурасының 2 нче утырышы протоколы https://islamperspectives.org/rpi/items/show/10507 (20.05.2020 каралды).

[2] Харәзем (Хива ханлыгы) – 1512–1920 елларда хәзерге Урта Азиянең бер өлешендә башта мөстәкыйль һәм, 1873 елда Рус империясе тарафыннан яуланып алынганнан соң, Русия протектораты рәвешендә яшәгән ханлык.

[3] Әсфәндияр хан (1871–1918) – 1910–1918 елларда Хива (Харәзем) ханлыгының хөкемдары.

[4] Бөтенрусия мөселман шурасының 3 нче утырышы протоколы https://islamperspectives.org/rpi/items/show/10510 (20.05.2020 каралды).

[5] Муса Бигиев. 1917 ел 1–11 майда Москва шәһәрендә гомум Русия мөселман съезды хакында кыскача мәгълүмат. Казан, 1917. 16 б.

## Казан: II Бөтенрусия мөселман корылтае

Муса әфәнденең иҗтимагый биографиясендә чираттагы зур һәм мөһим вакыйга 1917 елның 21 июлендә Казанда эшен башлаган II Бөтенрусия мөселман корылтае (II БРМК) була. Гомумән, ул җәйнең бу аенда Казан шәһәре бөтенрусия мөселман сәяси хәрәкәтенең үзәгенә әйләнә: апрель ахырында биредә I Бөтенрусия мөселман хатын-кызлары корылтае үткәрелә, II БРМК ачылуына санаулы көннәр калганда, Казанда тагын ике чара: I Бөтенрусия мөселман хәрби корылтае (17–25 июль) һәм 270 делегат катнашында I Бөтенрусия мөселман дин әһелләре корылтае (18–27 июль) эшләрен башлаган булалар.

II Бөтенрусия мөселман корылтаенда ике йөзгә якын делагат катнаша. 22 июльдә (яңача 4 августта) өч корылтай делегатларының уртак утырышында Садри әфәнде Максуди тарафыннан Эчке Русия һәм Себер мөселманнарының милли-мәдәни мохтарияте (автономиясе) турында Декларация укыла һәм бу көн татар халкының милли бәйрәме итеп таныла. Милли-мәдәни мохтарият (ММА) турындагы закон проекты II БРМКның 31 июльдә үткәрелгән утырышында кабул ителә. Документның 6 маддәсендә – ММА кысаларында эшләре татар телендә алып барыла торган мөстәкыйль хөкем итү (суд) системасының гамәлгә куелуы; 7 маддәдә – Русия күләмендә татар теленә дәүләт теле статусы бирелүе, 10 маддәдә – татар халкының Милли мәҗлесе (парламенты), 12 маддәдә милли хөкүмәт турында карарлар кабул ителгән була. Әлеге зур тарихи карарларны кабул итүдә Муса Бигиевнең дә актив катнашкан булуын истә тотарга кирәк. Аерым алганда, ул Милли мохтарият турындагы фикер алышуларда катнаша. Татар автономиясенең формасына кагылышлы тәкъдим ителгән өч проектның берсе аныкы була һәм «Милләт исламия мохтарияте» дип атала. Әлеге сәяси проект Русиядә яшәгән бөтен мөселманнарның дини һәм милли бәйсезлекләрен тәэмин итәргә тиеш була. Садри Максуди «Милли-мәдәни мохтарият» идеясен алга сөрә, коммунистик юнәлештә фикер йөрткән Галимҗан Ибраһимов «Татар мәдәнияте» дип аталган проект белән чыга.

Нәтиҗәдә, корылтай делегатлары Садри Максуди проектын заман таләпләренә күбрәк туры килә дип табалар һәм шуны сайлыйлар. Муса хәзрәт белән Садри әфәнде тәкъдим иткән ике проектның үзара охшашлыгы татарларның милли бәйсезлекләре мәсьәләсе белән генә чикләнгән була. Әмма проектларның колачлары, эш итү даирәләре төрле: Садри әфәнденеке Эчке Русия һәм Себер татарларын гына күздә тота, ә Муса хәзрәтнеке элеккеге империя чикләрендә яшәгән барлык мөселманнарны үз эченә алган була. Ягъни, Муса әфәнде татар милләте белән бергә мөселманнарны да кайгырткан.

Муса әфәнденең исеме 18–27 июльдә үткәрелгән I Бөтенрусия мөселман дин әһелләре корылтаена килгән делегатлар исемлегендә 226 нчы урында искә алына. Бу җыенда ул Петроград мөселманнары вәкиле буларак катнаша[1]. Дин әһелләре корылтаенда каралган мәсьәләләрнең берсе Русия мөселманнары өчен шәригать хөкемнәре буенча журнал булдыру мәсьәләсе була. Бу журнал, шулай ук, шәригать өлкәсендә җыелган каршылыкларны хәл итү, ягъни фикъһы методологиясе белән дә шөгыльләнергә тиеш табыла. Журналда сөнни исламда булган дүрт фикъһы мәзһәбенең һәммәсенә дә юл куелып, Төркестан, Кавказ, Кырым мөселманнары өчен уртак бер фикер алышу һәм тәҗрибә уртаклашу мәйданы буларак хезмәт итүе дә күздә тотыла. Нәтиҗәдә корылтайда журналның ике варианты тәкъдим ителә: беренчесе – Русия мөселманнары өчен журнал (ул 2–3 елдан чыга башлыйсы була), икенче вариант исә – бөтен дөнья мөселманнары өчен шәригать журналы. Бу эшне гамәлгә ашырыр өчен 20–30 ел вакыт карала. Журналны әзерләячәк Оештыру комитеты составына, Г. Баруди, Р. Фәхретдин, Х.-Г. Габәши[2], Зыяэтдин әл-Кәмали

---

[1] Голяма иттифакы. Беренче нәдвәсе. Төз. Ш. Шәрәф. Казан: типо-литография Т.Д. «Бр. Каримовы», 1917. Б. 57.

[2] Х.-Г. Габәши (Мөхәммәт углы Хасан-Гата Габәши; 1863–1936) – дин һәм җәмәгать эшлеклесе, фәкыйһ, төркиятче галим. Оренбург диния нәзарәтендә әгъза һәм казый. 1909 елда Уфада үзенең «Мофассал тарих кавем төрки» («Төрки кавемнәрнең тәфсилле тарихы») исеме фундаменталь тарихи хезмәтен бастыра.

кебек галимнәр белән беррәттән, Муса хәзрәт тә кертелә. Әмма бу әһәмиятле зур планнар тормышка ашмый кала, чөнки 1917 елның көзендә Русия тарихы чираттагы мәтәлчеген ата.

1917 елның көзенә таба илдә сәяси-иҗтимагый киеренкелек көчәя, хөкүмәтнең башбаштаклыклары, акылсыз хәрәкәтләре сәяси мәйданда давыллар уйната. Шундый хәлләрнең берсе 1917 ел августының соңгы көннәрендә (яңача сентябрь башында) кабынып киткән «Корнилов гыйсьяны» була: тамырларында кызу төрки каны аккан генерал Лавр Корнилов үзенә буйсынулы һәм күбесенчә Кавказ мөселманнарыннан торган «Вәхши дивизия»се белән тәртип урнаштырырга дип Петроградка яу чыга. Әлбәттә, дивизиянең «вәхши» дип аталуы аны тәшкил иткән гаскәриләргә түгел, мөселманнарны вәхши итеп күрергә күнеккән кара халыкның наданлыгына бәйле була. Вакытлы хөкүмәт рәисе Керенский, Корниловка гыйсьянчы тамгасы сугып, аны судка тарту турында карар чыгара.

Корнилов үзенә буйсынган дивизиясе белән башкалага бәреп кереп, анда кан коеп булса да, мөгаен, үзе теләгәнчә «тәртип урнаштыра» алган да булыр иде, әмма аның юлына Милли шураның башкарма һәйәте вәкилләре төшәләр һәм мөселманнардан торган коралды гаскәр белән уртак тел һәм килешү юлларын таба алып, «вәхши» дивизияне туктаталар. Нәтиҗәдә, Петроградта кан коелмый кала, халык башкарма һәйәт вәкилләрен һәм аларга ияреп шәһәргә кергән «вәхшиләрне» урамнарга чыгып алкышлап каршы ала. Корнилов кулга алына, аны туктаткан мөселман эшлеклеләрен олылап Керенский аларны ашка чакыра. Әмма тарих дәреслекләрендә бу фактлар, әлбәттә, телгә алынмый. Корнилов дивизиясенең мөселман активы тарафыннан туктатылуы Петроградта кызу сәяси эшчәнлек алып барган большевикларның да исән-имин калуларына хәлиткеч тәэсир ясавын истә тотарга кирәк.

### Большевиклар түнтәрелеше һәм вәхшәтнең беренче чаткылары

1917 елның 24 октябрендә большевиклар, кораллы восстание башлап, властьны көч белән үз кулларына алалар. Бу

көннәрдә Муса әфәнде әгъзалык кылган Милли шура большевиклар түнтәрелешен кабул итмәвен белдерә: 1917 елның 28 октябрендә МШБК үзенең өч вәкилен большевикларга каршы оештырылган Ватанны һәм революцияне коткару комитетына юллый; 10 ноябрьдә «Известия Всероссийского мусульманского совета» гәзитенең беренче сәхифәсендә, мөселманнар исеменнән большевикларга карата тискәре мөнәсәбәтен белдергән материал урнаштырып, аларга коралсыз каршылык күрсәтергә чакыра. Әмма 1917 елның 20 ноябрендә Халык комиссарлары советы рәисе Ленин һәм милләтләр эшләре буенча халык комиссариаты рәисе Сталин тарафыннан имзаланган «*Ко всем трудящимся мусульнамам России и Востока*» дип аталган мөрәҗәгать белән чыгалар. Документта мөселманнарның диннәре, гореф-гадәтләре, дини йолалар үтәлә торган бина һәм учреждениеләре «ирекле һәм кагылгысыз» дип игълан ителә. Бу сәяси адым Милли шураның большевикларга карата мөнәсәбәтен кискен сурәттә үзгәртә: ноябрьнең 10-ында ясалган игъланын гамәлдән чыгарып, 24 ноябрьдә Милли шура большевикларга теләктәшлеген күрсәтә, ә 30 ноябрьдә «Новая жизнь» гәзитендә А. Цаликов, «*Открытое письмо Совету народных комиссаров*» исемле язма бастырып, совет хөкүмәте белән хезмәттәшлек итү теләген белдерә. Бу юнәлештә күпмедер адымнар ясала, әмма, нәтиҗәдә мөселманнарның хөкүмәт белән арадашлык итүче органы буларак, Сталин тәкъдим иткән Үзәк мөселман комиссариаты (Центральный мусульманский комиссариат) исемле оешма төзелә һәм, аның рәисе итеп, Цаликов түгел, коммунист Мулланур Вахитов[1] куела. Ул арада 1918 елның гыйнвар аенда большевиклар Учредительное собраниене таратталар. Нәтиҗәдә ил

[1] Мулланур Вахитов (Муллаҗан углы Мулланур Вахитов; 1885–1918) – сәясәт һәм җәмәгать эшлеклесе, революционер, Гражданнар сугышында катнаша. Учредительное собрание әгъзасы итеп сайлана. Петроградта Ленин белән күрешә һәм аның киңәше белән 1918 елның 17 гыйнварыннан башлап Эчке Русия мөселманнарының эшләре буенча Комиссариат җитәкчесе итеп куела. КОМУЧ Халык армиясе Казанны яулап алганнан соң, кулга алына һәм атып үтерелә.

дә, халык та авыр сынаулар упкынына атыла, кешеләр башына йә бер бәла, йә бер афәт ишелеп тора: гражданнар сугышы, ачлык, эпидемияләр, бандитизм…

Шулай да, бу дәһшәтле өермә эчендә шатлыклы вакыйгаларга да урын табыла – 1917 елның 16 октябрендә Муса әфәндeнең гаиләсе бөтенләйгә Петроградка күчеп килә. Шулай итеп, Әсма ханымның күңел түрендә йөрткән күптәнге хыялы тормышка аша – алар, ниһаять, ишле гаилә булып бергә яши башлыйлар. Бу тормышлары нибары 13 ел – Муса әфәнде илне ташлап китәргә мәҗбүр булган 1930 елга кадәр дәвам итә. Муса әфәнде гаиләсенең бер булып, бердәм булып яшәгән унөч еллык дәвере, әлбәттә, бик кыска вакыт була. Әмма большевиклар кулында калган илдә 13 ел дәвамында кылыч астында гомер итү бик озак вакыт булса кирәк. Большевиклар кулында булып, исламга һәм мөселманнарга янаган бу кылыч инде 1918 елда ук күтәрелә: Казандагы «Мөхәммәдия», Уфадагы «Галия» белән «Госмания», Троицкидагы «Рәсүлия», Оренбургтагы «Хөсәения» мәдрәсәләре, татар газеталары һәм журналлары хөкүмәт тарафыннан ябыла. 1919 елның июнь аенда Казан губернасы мөхтәсибе Габдулла хәзрәт Апанай үлем җәзасына хөкем ителә, Галимҗан Баруди мөфти хәзрәтләре кулга алына.

Большевиклар түнтәрелешеннән соң башланган бу вәхшәтне күреп, мөмкинлеге булган һәркемнең, шул исәптән мөселман зыялыларының, татар җәмәгать эшлеклеләренең революциянең беренче елларында ук илне ташлап горбәтлеккә качып китә башлавына карамастан, Муса әфәнде нигә илдә калырга карар кыйлган? Беренче нәүбәттә, большевикларның хакимияткә килгән көннәрендә үк диярлек игълан иткән декретлары Муса әфәндене ышандырган булса кирәк. Ул декретларның кайберләре, аеруча «*Ко всем трудящимся мусульнамам России и Востока*» дип аталган мөрәҗәгать, большевикларның мөселманнарга карата хәерхаһ мөнәсәбәттә булуын белдергән ләбаса. Нәтиҗәдә хәтта Габдерәшит казый кебек тәҗрибәле сәясәтчеләр дә яңа властьта, үзләренең тарафдарларын күреп, аның белән хезмәттәшлек итүгә каршы

булмаганнар һәм кулларыннан килгән кадәр аңа ярдәм иткәннәр. Мәсәлән, Дәүләт иминлеге архивларында сакланган бер документта 1919 елда Тышкы эшләр халык комиссариатының (Наркоминдел) фәрманы белән, Идел буена һәм Шәрыкка инглиз империализмына каршы коралллы көрәш алып бару өчен, «панисламчыларның танылган юлбашчысы» Рәшит казый Ибраһим җитәкчелегендә бер экспедиция юлланылуы турында хәбәр ителә[1]. Рәшит казый белән тыгыз элемтәдә торган Муса әфәнде, әлбәттә, остазының большевикларга карата нинди мөнәсәбәттә торуын, Гражданнар сугышында кайсы көч яклы булуын белгән һәм үзенең позициясен дә, мөгаен, аңа карап корган булса кирәк.

Икенчедән (югарыда искә алынган документтан бу яхшы күренә), совет властеның башлангыч дәверендә большевиклар, Русиядәге революция ялкынын дөнья күләмендә таратып, дөнья халыкларын империализмга каршы сугышка күтәрә алачакларына тәмам ышанган булганнар һәм тышкы сәясәтләрен дә «социалистик цивилизация» төзү юнәлешендә алып барганнар. Шуңа күрә империалистик илләрнең колонияләре хәлендә калып, изелеп яшәгән Шәрык халыклары, аерым алганда мөселманнар, большевиклар тарафыннан тарафдарлар, союзниклар буларак кабул ителгәннәр. Шуңа күрә Совет властеның беренче елларында илнең тышкы сәясәтендә Шәрыкка бик зур игътибар бирелгән. Мондый шартларда тышкы дөнья мөселманнарын хәрәкәткә китерү эшендә большевиклар, әлбәттә, Русиянең үз мөселманнарына – аларның ярдәменә таянырга өметләнгәннәр. Бу турыда искә алынган мөрәҗәгатьтә бөтен Шәрык мөселманнарына большевикларга теләктәшлек белдерү һәм ярдәм күрсәтү турында ялкынлы үтенеч тә урын ала. Моннан тыш, 1918 елның 20 гыйнварында игълан ителгән Декретында Совет хөкүмәте диннең хөкүмәттән һәм мәктәпнең диннән аерылуын белдерә. Муса әфәнде өчен дә Совет хөкүмәте мөселманнар

[1] Гусева Ю. Н. Исламские лидеры Волго-Урала и публичная дипломатия Советской России 1920-х годов: достижения и проблемы // Ислам в современном мире. 2015. Т. 6. № 1. С. 19–26.

белән хезмәттәшлек корырга теләгән, аларның мәнфәгатьләрен аңлый торган власть булып күренә. Ул яңа власть белән хезмәттәшлек итүеннән Русия мөселманнарына, татарларга мөмкин кадәр зур дини, милли, мәдәни файдалар казанырга, һичшиксез, өметләнгән. Ягъни, Муса әфәнде ислам динен тоткан ватандашларының чын җанатары булган, үзен һәртөрле кыенлыкларга, хәтта куркынычларга дучар итүенә карамастан, үз халкы белән бергә булуны өстен күргән, киләчәккә карата да өметләр баглаган. Менә шундый сәбәпләр аркасында Муса әфәнде, хәтта большевик инкыйлабыннан соң да илне ташлап китмичә, биредә тагын 13 ел яши. Ниһаять, хәерле нәтиҗәләргә китерерлек эшләр эшләү мөмкинлеге яңа власть тарафыннан тәмам бетерелеп, киләчәккә караган барлык өметләр тәмам сүнгән көндә, үзенә дә котылгысыз һәлакәт якынайган минутта, илен ташлап, читкә китәргә мәҗбүр була.

Алга таба сүзебез Муса әфәнденең Совет власте астында яшәгән еллары турында булачак.

1917 елның ахырына таба Муса әфәнде Петроградта «Әманәт» нәшриятының идарә вәкилләре белән бергәлектә «Әл-Минбәр» исемле татар гәзите чыгара башлый. Яңа гәзитнең идарә вә редакциясендә башкаланың күренекле татар мөселман зыялылары эшлиләр. Муса әфәндегә вакытлы сурәттә баш мөхәррир вазифалары йөкләнә. «Әл-Минбәр» гәзите инкыйлаб дәверенең катлаулы вазгыятендә халыкка татар милли-мәдәни мохтариятенә кагылышлы мәсьәләләрне, аның эшчәнлеген яктырту, Русия мөселманнарының сәяси оешмалары буларак, Петроградта эшләп килгән Милли шураның, Вилаять шурасының активлыгы белән таныштырып тору өчен корыла. Гәзитнең көн саен чыгуы планлаштырылган була. Бүгенге көндә аның өч саны чыккан булуы мәгълүм: беренчесе – 24 декабрьдә, өченчесе – 1918 елның 17 мартында.

Гәзитнең беренче санында аны нәшер итүчеләр үз исемнәреннән кереш редакцион мәкалә бастыралар. Әлеге мәкалә «Әл-Минбәр» гәзитенең мәсләген бәян иткәнгә күрә, аның кыскартылган вариантын биредә китерү урынлы булыр: «*Зур бәлаләрнең, дәһшәтле зәхмәтләрнең татлы сәмәрәләре,*

*бәрәкәтле нәтиҗәләре буларак, Русиядә инкыйлаб көннәре, революция хәрәкәтләре башланып, соң булса да, Русия мөселманнарының бөтен куәте белән милли-мәдәни мохтариятыбыз игълан кыйлынды. Мохтарият һәйәте дә, милләтнең бөтен идарәләре дә, һәммә мөъәссәсәләре дә эш башлады.*

*Милләтнең ихтыяҗлары гаять күп, эш мәйданнары киң, юл ачык, тарихның шу көнге дакыйкалары да гаять мөһим. Шу көн вазифаларның әһәмиятләре дә артты... Безнең ширкәт матбагасы китап базарына, милләтнең әдәбиятына, мәктәп-мәдрәсәләрнең ихтыяҗларына хезмәт итмәк арзусы белән корылды... Петроградта мөселманча милли, әдәби, иҗтимагый, сәяси бер җәридә нәшер итмәк, әлбәттә, лязем иде.*

*Наширләр: Галим Максудов, Мостафа Исмәгыйль, Мөхәммәдшаһ Җиһаншаһ, Гыймадетдин Җәмал, Гомәр Галәветдин, Лотфулла Җәмал, Әхмәтҗан Төхфәт, Зиннәтулла Вафа, Әхмәдшаһ Әхнәзи, Кәмал Байбулат, Сафа Исмәгыйль, Галләметдин Атийтәр, Мәхмүд Юмай, Сөнгатулла Гата, Кәрим Нугай, Галим Нугай, Зиннәтулла Гыймад, Имаметдин Хусам, Лотфулла Исхакый, Хөсәен Бичура*».

Петроградта татар-мөселман җәмәгатьчелегенең раһбәрләре һәм актив эшлекклеләренең бу исемлектә санап чыгылган атлары, шиксез, тарихи әһәмияткә ия. Шуңа күрә ул исемнәр тикшеренүчеләрнең игътибарын, мөгаен, җәлеп итәр, дигән өметтә калам.

Инде Муса әфәнденең 1917 елда чыккан «*Исляхат әсасләре*» белән «*Шәригать әсасләре*» исемле китапларына кыска гына күзәтү ясап узыйк.

«*Исляхат әсасләре*»нә килгәндә, бу җыентыкны Муса әфәнде дәвамлы итеп, киләчәктә аның икенче томын да язарга ниятләгән булган: «*Зур бер гозерем бар иде. Шуңа күрә, бу китабымны ике бүлек итеп, берсен 288 нче сәхифәдә мәҗбүри сурәттә тәмамладым.*

*Милләтнең бәяләвенә күрә, бу китапның әһәмияте булса, мөхтәрәм укучылар миңа бәлки ярдәм итәрләр: киңәшләрен, уй-фикерләрен ачык һәм ирекле сурәттә язып, сәяси, иҗти-*

*магый хәрәкәтләребезгә кагылышлы мәгълүматларын, документларын миңа бәлки күндерерләр; 1904–1916 елларына кагылышлы дөрес мәгълүмат басылып таратылыр иде.*

*Моннан соң бәлки, бүгенге мөхарәбә бөтен яклары белән ачыкланып һәм бәян кыйлынып, Русия мөселманнарының каләме белән, тырышлыгы белән махсус бер китап – бер мәҗмуга бәлки нәшер кыйлыныр.*

*Бөтен мәдәниятнең тәмам асты өскә килүенә зур сәбәп булып, исламият дөньясына да һәрьяклап тәэсир итәчәк сугыш хакында бер җыентык нәшер итү безгә, мөселманнарга, әлбәттә, тиештер, зарурдыр.*

*Муса Җаруллаһ, 1917 февраль 3 тә*» (хәзерге татар теленә тәрҗемә).

Шулай итеп, әлеге китапның беренче томына гына дөнья күрү насыйп булган. Әмма Русия мөселманнарында сәяси-иҗтимагый хәрәкәтләр тарихы өчен аның бер томы кыйммәтле чыганак булып тора. Бу нисбәттән, китапның эчтәлеге белән таныштыру урынлы булыр: «*Иҗтимагый хәрәкәтләребезнең тарихы (б. 2–12); Уфада голәма җәмгыяте «Корылтае» (б. 12–16); Закавказье сөнни мәзһәб мөселманларының идарәи руханияләре хакында карар (б.18–35); Оренбург Собраниесының статьялары (б. 36–39); Корылтай мәҗлесләре (б. 39–42, 50–52); Шәйхелисламлык мәсьәләсе (б. 10,39,42); Риза әфәнде ляихәсе (б. 52–57); Корылтайның соң мәҗлесләре (б. 77–79); Уфада шәкердләрнең гаризасы (б. 79–82); Хәзрәтләрнең таләбләре (б. 82–84); Габдулла әфәнде Дибирди гаризасы (б. 84–85); Тын карьяләрендән зур тавыш (б. 86–91); йәнә ляихәләр (б. 91–99); Хәсән-Гата казый ляихәсе (б. 99–105); Мохталит һәйәт[1] мәҗлесләре (б. 108–112); Уфа ляихәсе (б. 112–136); Башкорт вәкилләренең ляихәсе (б. 136–138); Корылтай ляихәләренең халкы фикеренә тәэсире (б. 132–150); Хөкүмәт намына вирелмеш гаризалар (б. 151–159); Кавказ мөселманнарының гаризалары (б. 159–162); «Иттифак» мәҗлесләре (б. 162–169); Тарихи мәҗлес (б. 169–175); Август 15 карары иттифак низамнамәсе (б. 176–181); Инкый-*

[1] мохталит һәйәт – катнаш комитет.

*лаб көннәре үктәбер 17 манифесты (б. 182–194); Русиядә сәяси партияләр (б. 194–201); «Иттифак»ның икенче съезды (б. 201–240); Иттифак програмы (б. 220–233); Март 31 правилалары (б. 242–251); Дини мәктәбләр-мәдрәсәләр хакында мөәллифинең мөляхәзаләре (б. 251–257); Конституция статьялары (б. 257–275); Дәүләт думасының низамлары (б. 276–286); Әсас канунлара даъир мөляхәзаләр (б.286–289)».*

Кушымтада укучылар игътибарына әлеге исемлектән «*Дини мәктәбләр-мәдрәсәләр хакында мөәллифинең мөляхәзаләре*» исемле язманың тәрҗемәсе тәкъдим ителде[1]. Анда Муса әфәнденең милләтнең яшәешен тәэмин итә торган әлеге стратегик мәсьәләгә нинди мөнәсәбәттә булуы, никадәр әһәмият бирүе һәм аны хәл итү өчен нинди чаралар тәкъдим итүе яхшы күренә.

## «Шәригать әсасләре»

«***Шәригать әсасләре***» – Муса әфәнденең Русиядә басылган соңгы китапларының берсе. Бу әсәр гаять үзенчәлекле, чөнки шәригать теориясен, аның фәлсәфәсен бәян итә. Мондый төр әсәрнең барлыкка килүе шәригатькә кагылышлы мөселман әдәбиятында бөтенләй яңа сүз, яңа күренеш була. Шәригать китаплары Муса әфәндегә кадәр гасырлар дәвамында язылган, аларны санап бетергесез. Ул әсәрләрдә, аеруча ислам хокукының теориясе һәм методологик принциплары белән шөгыльләнә торган усулы фикъһы гыйлеменә караган китапларда хокукның табигате, аның чыганаклары, канун тарафыннан якланырга тиешле асыл кыйммәтлекләр, дин күзлегеннән карап хокукка нигез салу кебек мәсьәләләр күпмедер дәрәҗәдә, әлбәттә, каралган. Әмма Муса әфәнденең бу китабы гасырлар дәвамында үстерелгән усулы фикъһыны һәм, гомумән, шәригатьне гомумиләштерү рухында язылып, аның гомумкешелек цивилизациясе кимәлендә нинди урын алуын һәм перспективаларын күрсәтүгә багышланган.

[1] Карагыз: III Бүлек. 11: «Дини мәктәбләр, мәдрәсәләр хакында төзүченең мөляхәзалары».

Китабының эчтәлегенә Муса әфәнде түбәндәге мәсьәләләрне керткән: Ислам диненең кешеләр тарафыннан иҗат ителгән (мәдәни) һәм күктән иңгән (сәмави[1]) шәригатьләргә (законнарга) мөнәсәбәте; ислам шәригатенең хакыйкыйлыгы, шәригатьнең нигезләре һәм чыганаклары; Коръәннең кешеләргә карата куйган таләпләренең аңлатмасы; Коръәннең чынбарлык күренешләренә, табигать дөньясының хакыйкатьләренә караган ачык, аңлаешлы һәм күпсанлы бәяннары; һәр шәригатьтә булган ике төркем хөкемнәр; хиҗаб мәсьәләсе һәм аны хәл итү; «Коръән кәримдә шигырьлек бармы?» – дигән сорауга җавап; Коръән кәримнең гомумилеге һәм мәңгелеге; фикъһы[2] мәзһәбләренең[3] тарихларына, оешуларына, методологик нигезләренә кагылышлы кыска бер аңлатма; усулы фикъһы[4] турында китапны язучының тоткан мәзһәбе; Коръәнгә хөрмәт күрсәтү йөзеннән мөселманнарның башкарырга тиешле вазифалары; хатын-кызларның хөрмәт ияләре булуы һәм аларның хокуклары.

Биредә әлеге әсәрне ачып җибәргән һәм шәригатьнең ни икәнлеген аңлаткан бер парча китерү урынлы булыр:

---

[1] сәмави/сәмавия (гарәп.: сәмаъ – күк) – күктән иңдерелгән.

[2] фикъһы (гарәп.: тирәнтен аңлау, нәрсәнең дә булса асылын аңлап, белеп эш итү) – мөселманның үз-үзен тотышы кагыйдәләре турындагы тәгълимат, мөселманның хокук вә вазифалары турындагы фән. Киң мәгънәдә – ислами хокук (исламское право, мусульманская юриспруденция). «Әгәр Аллаһ берәүгә яхшылык теләсә, Ул аңа динне тирәнтен аңлауны насыйп итә (йәфкаһу-һу)» (ышанычлы (сахыйх) хәдис). Фикъһы сүзе әлеге хәдистә кулланылган йәфкаһу (динне тирәнтен аңлауны насыйп итә) дигән фигыльдән ясала.

[3] фикъһы мәзһәбләре – фикъһыда, ягъни ислами хокук фәнендә барлыкка килгән дүрт методологик юнәлеш, дүрт хокук мәктәбе: хәнәфи мәзһәб (имам Әбү Хәнифә мәзһәбе), мәлики мәзһәб (имам Мәлик мәзһәбе), шәфигый мәзһәб (имам әш-Шәфигый мәзһәбе), хәнбәли мәзһәб (имам Ибне Хәнбәл мәзһәбе).

[4] усульләр (фикъһы усульләре; усулы фикъһы) – фикъһы гыйлеменең тамырлары, ягъни шәригать хөкемнәрен чыгаруда кулланыла торган асыл кагыйдә һәм алымнары.

*«Минем карашымча, ислам шәригате элеккеге шәригатьләрнең кямилләштерелгән иң яхшы күчермәседер:* (شَرَعَ لَكُم مِّنَ الدِّينِ مَا وَصَّى بِهِ نُوحًا وَالَّذِي أَوْحَيْنَا إِلَيْكَ وَمَا وَصَّيْنَا بِهِ إِبْرَاهِيمَ وَمُوسَى وَعِيسَى)[1].

*Табигать хәрәмендә[2], Раббының өзлексез багуы белән хисапсыз гасырлар дәвамында тәрбияләнеп, кешелек дөньясы мәдәнияткә, мәдәни яшәеш дәрәҗәләренә иреште. Кешелек дөньясы хәят мәктәпләрендә, Өлүһият[3] остаханәләрендә дәрес укып, хәят кануннарын, яшәеш кануннарын өйрәнде. Кеше нәрсәне генә белсә дә, ул белемнәрнең һәммәсен Аллаһ тарафыннан бирелгән гыйлем буларак белде.*

(اقْرَأْ بِاسْمِ رَبِّكَ الَّذِي خَلَقَ خَلَقَ الْإِنسَانَ مِنْ عَلَقٍ اقْرَأْ وَرَبُّكَ الْأَكْرَمُ الَّذِي عَلَّمَ بِالْقَلَمِ عَلَّمَ الْإِنسَانَ مَا لَمْ يَعْلَمْ)[4]

*Шуңа күрә, минем фикеремчә, төрле заманнарның, төрле урыннарның, төрле милләтләрнең гаделлекне һәм дөреслекне яклаучы шәригате ул Күктән иңгән шәригать була, Аллаһтан бирелгән илаһи шәригать була:* (وَإِن مِّنْ أُمَّةٍ إِلَّا خلَا فِيهَا نَذِيرٌ)[5] – (وَلِكُلِّ قَوْمٍ هَادٍ)[5]*, дигән бәһасез айәтләр дә әлеге хакыйкатьнең дөреслеген раслыйлар.*

*Мәдәни бер халыкның шәригате нинди генә булса да, ягъни ул хикмәт вә акылияләре тарафыннан җитештерелеп гамәлгә куелган хикмәт булса да, яки пәйгамбәрләрнең теле белән җиткерелгән илаһи күрсәтмәләр булса да, аларның һәрбере Аллаһның кешеләр белән корган килешүедер. Ягъни ул шәригатьләр Аллаһның вәгъдәсе белән, кешелек дөньясының үз өстенә йөкләве белән карар кыйлынган, ягъни имза-*

---

[1] «Ул Нухка васыять иткәннәрен, Безнең сиңа вәхи кыйлганнарыбызны, һәм Ибраһимга, һәм Мусага, һәм Гайсәгә васыять иткәннәребезне диндә сезнең өчен канунлаштырды» (42:13).

[2] хәрәм – тыюлык; храм.

[3] өлүһият – илаһилек, илаһиять.

[4] «Барлыкка китергән Раббыңның исеме белән, укы! Ул кешене бер куерыктан барлыкка китерде! Укы! иң олы җанлыдыр синең Раббың! Ул каләм белән өйрәтте: кешегә белмәгән нәрсәләрен өйрәтте!» (96:1–5).

[5] «һәр халыкның туры юлга күндерүчесе бар» (13:7).

*ланган килешүдер:* (إِنَّا عَرَضْنَا الْأَمَانَةَ عَلَى السَّمَاوَاتِ وَالْأَرْضِ وَالْجِبَالِ فَأَبَيْنَ أَن يَحْمِلْنَهَا وَأَشْفَقْنَ مِنْهَا وَحَمَلَهَا الْإِنسَانُ إِنَّهُ كَانَ ظَلُومًا جَهُولًا)[1].

*Бу илаһи килешү тормышның төрле хәлләрендә аңа турылыклы булып калу кебек, иҗтимагый тәртипкә караган мөгамәләләрдә гаделлек һәм хакыйкатькә хилафлык китермәү кебек вазифаларны башкаруга кайтып кала иде:* (أَلَمْ أَعْهَدْ إِلَيْكُمْ يَا بَنِي آدَمَ أَن لَّا تَعْبُدُوا الشَّيْطَانَ إِنَّهُ لَكُمْ عَدُوٌّ مُّبِينٌ وَأَنْ اعْبُدُونِي هَذَا صِرَاطٌ مُّسْتَقِيمٌ)[2].

*Гаделлек, хакыйкатькә турылыклылык, әдәплелек вазифаларының барысы да Аллаһның бөеклеге каршында кешенең гыйбадәте булып, золым, хыянәт, әдәпсезлек кебек яманлыкларның һәммәсе дә шайтанның тәкәбберлеге каршында кешеләрнең гыйбадәтедер. Кешелек дөньясында һәр гасырның, һәр милләтнең шәригате ул илаһи шәригать иде. Илаһи ярдәм һич кайсы гасырда һичбер милләтне, санга сукмыйча, әйләнеп узмады:* (أَيَحْسَبُ الْإِنسَانُ أَن يُتْرَكَ سُدًى)[3] – (أَفَحَسِبْتُمْ أَنَّمَا خَلَقْنَاكُمْ عَبَثًا وَأَنَّكُمْ إِلَيْنَا لَا تُرْجَعُونَ)[3].

*Ләкин шәригатьләр гасырларның, заманнарның, милләтләрнең үзгәреп торуларына күрә төрле булып, кямилләшү кебек илаһи кагыйдәгә буйсынып, соңрак килгән шәригать үзеннән элек булган шәригатьләрнең камилләшүе кебек була иде. Мәдәни тормыш итү дәвамында заман кулы белән ислях кыйлынып, төзекләндерелеп килгән шәригатьләрнең, кануннарның азагында күктән иңгән шәригать буларак иңгән исламият әүвәлге шәригатьләрнең һәм кануннарның саф җәүһәрләрен, матур нигезләрен тулысынча җыеп, алар-*

[1] «Без күкләргә, җиргә һәм тауларга әманәт тәкъдим иткән идек, ләкин алар аны үз өсләренә йөкләүдән баш тарттылар һәм куркып калдылар. Ул әманәтне үз өстенә кеше алды, чөнки ул залим иде, яман иде» (33:72).

[2] «Әй, адәм балалары! Мин сезгә: «ачыктан-ачык дошманыгыз булган шайтанга» гыйбадәт кыйлмагыз! Миңа гыйбадәт кыйлыгыз, будыр тугры юл!» – дип кисәтеп куймаган идеммени?» (36:60–61).

[3] «Сезне Без бер уен-көлке өчен генә барлыкка китергәнбез, дип уйлап, үзегезне Безнең янга әйләнеп кайтарылмыйсыз, дип уйлыйсызмы әллә?» (23:115).

*га хас булган табигый җитешсезлекләрне төзәтеп, барлык шәригатьләрне гамәлдән чыгарды, ягъни ул шәригатьләрнең иң яхшы нөсхәсе булу шәрәфе*[1] *белән бөтен кешелек дөньясы өчен уртак мәрхәмәт булды*»[2].

Муса әфәнденең бу хезмәте турында берникадәр тирәнрәк белем бирү йөзеннән, кушымтада аның бер өлеше китерелә[3]. «*Шәригать әсасләре*» хәзерге көндә Россиядә эшләп килгән мөселман уку йортларында шәригать һәм фикъһы факультетларында өйрәнелә торган бер чыганакка әйләнер дигән өметтә калам.

## Афәт еллары

1918 ел дәвамында Русиядә Гражданнар сугышы көчәйгәннән-көчәя бара, ил халкын ачлык элмәге буа. Яңа шартларда большевиклар, шул исәптән мөселман большевиклар тырышлыгы белән сәяси эшчәнлек мәйданыннан читкә этәрелгән Милли шура вәкилләре, 1918 елның 3 февралендә Петроградта җыелышып, әлеге оешманың 1 марттан юкка чыгарылуы турында карар кабул итәләр. Большевик хакимиятенең беренче алты ае шулай тәмамлана.

Бу үзгәрешләр дәверендә Муса әфәнде беренче урынга гаиләсен афәтләрдән коткаруны куя: ул азык-төлек эзләү белән мәшгуль булып, ил буйлап йөрергә мәҗбүр була. Әледән-әле Төркестаннан килеп торган дуслары алып килгән күчтәнәчләре белән Муса әфәнденең аш табынына ямь өстиләр. Андый чакларда Муса әфәнде, гадәттәгечә, үзен генә түгел, мохтаҗларга, дус-ишләренә, коллегаларына да өлеш чыгара. Шундый бер вакыйга турында миңа мәрхүмнең кече кызы Фатыйма ханым үзе сөйләгән иде. Совет дәвере, торгынлык чоры. Лениградта күренекле шәркыятьче галим, академик

---

[1] шәрәф – мәртәбә (гарәп.), дәрәҗә (гарәп), абруй (фарс.). Борынгы телебездә: кешенең ярамыгы, яхшысы, торыры.

[2] Өзек хәзерге татар теленә тәрҗемә ителде.

[3] Карагыз: III Бүлек. 12: «Шәригать әсасләре» исемле китаптан.

Крачковскийның[1] юбилеенә багышланган чаралар үткәрелә. Шуларның берсендә Фатыйма ханым да булып түбәндәге хатирәләрен язып калдыра: «*Шунда аның хатыны[2] хатирәләре белән уртаклашканда Муса Бигиевне дә искә төшерде. Матди яктан авыр елларда (1919 яки 1920 еллар) алар христиан бәйрәме көнне буш өстәл янында кайгырып утырганнар. Кемдер ишек шакыган, ачсалар – Муса Бигиев, ниндидер ашамлыклар китергән. Шул көннәрдә әтиемә Урта Азиядән кемдер килгән булган, күчтәнәч китергәннәр, шуның бер өлешен әтием Крачковскийларга биргән (якын танышлар да түгел югыйсә, ә галимгә хөрмәт йөзеннән) Крачковская ханым ашамлыклар китергән Муса Бигиевнең дикъкатен оныта алмыйм дип сөйләде. Бер сүз әйтмичә генә (мине Муса Бигиевнең кызы дип җыелган кешеләр белмиләр иде), әтием хакында шундый җылы сүзләр ишетеп горурланып утырдым*»[3].

Академик Крачковский үзе дә Муса әфәнде турында яхшы фикердә була. Мәсәлән, 1948 елда Шәрыкны өйрәнү институтында (Институт востоковедения) академикның фәнни хезмәтләре буенча фикер алышу үткәрелгән була. Мәскәүдән

---

[1] Крачковский (Игнатий Юлианович Крачковский; 1883–1951) – Россия империясенең һәм Советлар берлегенең атаклы шәркыятьче галиме, гарәп теле белгече, тарихчы, филолог, археограф, 450-гә якын фәнни хезмәт авторы; 1910 елдан Петербург университеты приват-доценты, 1918 елдан Петроград-Ленинград дәүләт университеты Шәрык факультетының гарәп шигърияте, христиан-гарәп язма мирасы һәм хәзерге заман гарәп әдәбияты профессоры; 1921 елдан Россия (1925 елдан СССР) Фәннәр академиясе академигы; Совет гарәбиятенә нигез салучыларның берсе; Сталин премиясе лауреаты (1951); Коръәннең рус теленә тәрҗемәсенең авторы, «Ислам энциклопедиясе»нең беренче басмасын язган авторларның берсе; «Мең дә бер кичә» мәҗмугасының рус теленә ясалган беренче тәрҗемәсенең мөхәррире.

[2] Сүз академик Крачковскийның хатыны – совет Шәрык белгече, сәнгать тарихчысы Вера Александровна Крачковская (1884–1974) турында бара.

[3] Фатыйма Бигиева-Таһирҗанова. Әтием хакында хатирәләр. С. 174.

килеп чыгыш ясаган Л. Климович[1], Крачковскийга шикаять белдерү йөзеннән, аның бер хезмәтендә Көнбатышка качып киткән белогвардеец Б.ны, ягъни Бигиевне искә алуда гаепләп чыга. Шунда Крачковский куркып калмыйча, Б.ның гарәп теле һәм әдәбияты буенча бик зур белгеч һәм бик мәгърифәтле («высокообразованнейший») кеше булганлыгы турында әйтеп аны яклый[2].

1918 елда Муса әфәнде сәяси карашлары өчен эзәрлекләнүгә дучар ителгән дусты, Милли шура буенча көрәштәше Садри Максудига илнең чиген яшерен рәвештә узып Финляндиягә чыгып качарга ярдәм итә[3]. Тагын берничә елдан Максуди үзенең гаиләсен дә коткару юлларын эзләп, кабат мөрәҗәгать итә. Муса әфәнде кулыннан килгәннәрне эшли һәм 1922 елда Финляндиядә Максудига гаиләсе белән янә кавышу насыйп була.

1918 елда Муса әфәнде «***Гаилә мәсьәләләре***»[4] исемле бер китап бастырып чыгара. Аның турында 1975 елда Әнкарада төрек теленә тәрҗемә ителеп чыгарылган «***Озын көнләрдә рузә***»нең кереш сүзендә Муса әфәнденең үз кулы белән язган исемлекнең нөсхәсеннән укып белә идек, ә бу китапны язган көннәрдә әлеге әсәр Россия Милли китапханәсендә (РНБ) табылды. Бүгенге көндә «*Гаилә мәсьәләләре*» Муса әфәнденең ватанында басылып чыккан иң соңгы әсәре булып тора. Муса әфәнденең моннан соң язылган хезмәтләренең һәммәсе дә чит илләрдә чыкканнар.

---

[1] Климович Л. (Люциан Ипполитович Климович; 1907–1989) – совет шәркыятьче галиме, әдәбият һәм ислам белгече, профессор; 1931–1933 елларда Казанда Татар педагогия институтында укыткан; 500 ләп фәнни хезмәтләр авторы, шул исәптән «Атеистический словарь» һәм ислам диненә каршы язылган әсәрләр иҗат иткән.

[2] Рахимкулова М.Ф. Медресе «Хусаиния» в Оренбурге. Оренбург: «Яңа Вакыт», 1997. С. 44.

[3] Айда Адиле. Садри Максуди Арсал. С. 117.

[4] Муса Җаруллаһ. Гаилә мәсьәләләре. Петроград: [Амәнәт], 1918. 26 б.

## Яңадан Бәрәкәтуллаһ һәм Ленин белән күрешү

Муса әфәнденең тормышында 1919–1920 еллар да җиңелләрдән булмый. Ил язмышы кыл очында эленеп торып, халык өстенә төрледән төрле афәтләр, сугышлар, эпидемияләр, ачлыклар ишелеп торган бу дәвердә Муса әфәнде китапларын бастыру мөмкинлегеннән мәхрүм ителә. Нәтиҗәдә, еллар дәвамында үз иҗатының җимешләре хисабына көн күргән галимнең матди хәле бик начарая. Гаиләсен тәэмин итеп торыр өчен ул, хәтта, он, тоз кебек нәрсәләр сатып, сәүдә белән шөгыльләнергә мәҗбүр була. Әмма тормыш, һәрхәлдә, дәвам итә – Русиягә янә Мәүләви Бәрәкәтуллаһ килеп төшә һәм ярты ел дәвамында Муса әфәнденең кунагы була. Бу турыда китапларының берсендә Муса әфәнде мондый сүзләр язып калдырган: «*Москвада айларча бергәләп яши идек. 1919–20 нче елларда Русия вилаятләрендә берничә ай бергәләп сәяхәт иттек. Мин он, тоз кебек кирәкле нәрсәләр эзләдем…*».

Ул чакта сәяси эшчәнлекләре аркасында Британия колониаль идарәсе тарафыннан Бәрәкәтуллаһ белән бергә Һиндестаннан башка күренекле мөселман сәясәтчеләре һәм җәмәгать эшлеклеләре куыла. Берара алар Советлар илендә торып алалар, һәм шул чакта Муса әфәнде Мәүләви Гобәйдуллаһ әс-Синдһи, Әбу Сәгыйд әл-Гарабә, Мәүләви Габрерраб, Мәүләви Габделҗаббар, Мәүләви Габдессаттар һәм Раҗә Махандра Пратап кебек шәхесләр белән аралашу, фикер алышу мөмкинлегенә ия була, алардан ишеткән идеяләр белән үзен рухиятен баета, сәяси карашларын киңәйтә.

Бәрәкәтуллаһ һәм аның көрәштәш ишләре Һиндестанны Бөекбритания изүеннән коткаруда Совет хөкүмәтеннән ярдәм күрергә өметләнәләр. Дөресен әйткәндә, Русиягә Бәрәкәтуллаһ Әфганстан әмире Әманулла-Ханның йомышы белән килә – Әманулла-Хан Ленин белән берләшеп Шәрыкта Бөекбританиягә каршы уртак стратегия булдырырга өметләнгән Муса әфәнде, көтмәгәндә, ике ил арасындагы сәяси мөнәсәбәтләр төзелүе процессында катнаша. Һәрхәлдә, Муса әфәнденең кунагы буларак Бәрәкәтуллаһ, бер яктан, Совет иле

белән якыннан таныша, халык белән аралаша, икенче яктан, митингларда һәм собраниеларда Британия империализмына каршы ялкынлы чыгышлар ясый, Совет властен мактый, большевиклар белән Һиндестан мөселманнарын берләштерә торган уртак сәяси максатлар турында сөйли. Вакыты җиткәч, Бәрәкәтуллаһның бу активлыгы Сталинның игътибарын җәлеп итә һәм ул ике дусны үзенә чакыртып ала. Алар белән аралашканнан соң, Сталин аларга Ленин белән күрешү оештыра. Шулай итеп, үзенең күптәнге дусты Бәрәкәтуллаһның бәрәкәте белән Муса әфәндегә большевик инкыйлабының җитәкчесе белән күрешеп сөйләшергә насыйп була. Бәрәкәтуллаһ белән бергә Муса әфәнденең дә кабул ителүе Совет властеның Шәрык сәясәтендә аның белән бәйле булган җитди планнар коруына һәм өметләр баглавына дәлил булып тора.

Муса әфәнденең Ленин белән күрешүе турында без коммунист-мөселманнарның берсе булган Мирсәет Солтангалиевнең[1] 1919 елның 27 августында Ленинга язган хатыннан беләбез. Хатта Солтангалиев үзен «один из главных инициаторов и активных борцов с мусульманскими буржуазно-соглашательскими организациями в Советской России» дип билгели һәм Бөтенрусия мөселман хәрби шурасы, Бөтенрусия мөселман милли шурасы, Эчке Русия мөселманнарының Милли мәҗлесе кебек оешмаларны юк итүне үзенең бер казанышы итеп күрсәтә. Хатта мондый сүзләр дә бар: «*Мне и работающим вместе со мной товарищам коммунистам-татарам крайне обидно, что руководители революционного движения мусульман внутренней России после смерти Муллануры Вахитова не удостаиваются приема с Вашей стороны, тогда как к Вам имеют свободный доступ мусульманские националисты (З. Валидов, Баракатулла, Муса Бигиев и другие*»[2].

[1] Мирсәет Солтангалиев (Хәйдәр-Гали углы Мирсәет Солтангалиев; 1892–1940) – революционер, ислам сәясәт эшлеклесе, РСДРП(б) әгъзасы, Татар Республикасына нигез салучыларның берсе.

[2] Мирсаид Султан-Галиев. Избранные труды. Казань: Издательство «Гасыр». 1998. С. 197.

Бу хаттан аңлашылганча, Совет властеның беренче елларында хөкүмәт тышкы мөселман дөньясы белән аралашу һәм аңлашуны эчке мөселман җәмәгатьчелеге белән хезмәттәшлек итүдән әһәмиятлерәк күргән. Мәсәлән, 1919 елның язынннан Кызыл Армия Төркестандагы активлыгын нык көчәйтә. Кызылларның максаты мөселманнар яшәгән әлеге территорияләрне (Бохара, Хива-Харәзем, Куканд, Ташкент һ. б.) тулысынча Мәскәүгә буйсындыру гына булмый – Кремль үзенең Төркестандагы хәрбиләре алдына тагын да зуррак максатлар куя. Кызыл Армия, Төркестан җирләреннән һөҗүм башлап, чиктәш Әфганстанны һәм Иранны яулап алырга җыена. Шулай ук Кызыл Армиянең Азәрбайҗандагы гаскәре, Иранга Каспий диңгезенең көньяк-көнбатыш тарафыннан бәреп кереп, бу борынгы илне дә яулап алуда катнашырга тиеш була. Бу нисбәттә Совет властеның 1920 елда Бакуда Шәрык халыклары съезды үткәрергә планлаштыруы да яхшы аңлашыла. Нәкъ әнә шуңа күрә Совет властена тышкы сәясәтнең Шәрык юнәлешендә файда китерә алачак кеше буларак каралган Муса Бигиевкә югары кабинетларга юл ачылган, ә Солтангалиевкә һәм аның ишләренә игътибар ул кадәр булмаган.

## Шәйхелислам Мостафа Сабри тарафыннан тәнкыйть

Шул ук 1919 елда Госманлы Дәүләти Галиясенең шәйхелисламы итеп куелган Мостафа Сабри[1] хәзрәтләре Муса әфәнде һәм аның кебек башка мөҗәддидләрне тәнкыйтьләү йөзеннән «*Дини мөҗәддидләр йахуд «Төркия ичүн нәҗат вә игътиля йуллары»нда бер раһбәр*» исемле китап яза[2]. Күләм-

[1] Мостафа Сабри (Мостафа Сабри Токади; 1865–1954) – госманлы төрек дин эшлеклесе, галим, шәйхелислам (1919). 1922 елда Каһирәгә күчеп китә, «әл-Әзһәр» университетында укыта, «Мәукыйф әл-гакли» исемле китабын язып, анда Җәмалетдин әл-Әфгани, Мөхәммәт Габдүһ кебек исляхчыларны тәнкыйтьли.

[2] Мостафа Сабри. Дини мөҗәддидләр йахуд «Төркия ичүн нәҗат вә игътиля йуллары»нда бер раһбәр. Шаһзадә башы: Уфак матбагасы. 1338–1340. 374 б. Китапның исеменнән аңлашылганча, Сабри әфәнде аны югарыда искә алынган Һашим Нәһитнең «Төркия ичүн нәҗат вә игътиля йуллары» исемле әсәренә тәнкыйть бу-

ле бу китапта автор Муса әфәндегә багышлап «*Казанлы Муса Бигиев әфәнденең гыйлеме кәлямемез хакындаки суъи занны*»[1], дип исемләнгән бер бүлекчә урнаштырып, татар галименең кәлям гыйлеменә карата булган фикерләренең дөрес булмавын дәлилләргә тырышкан. Сабри хәзрәтләренең Муса әфәндене мөҗәддид, ягъни яңартучы, дип атавы аерым игътибарга лаек. Бу сүз белән Сабри хәзрәтләре, мөгаен, үзе дә теләмәстән, Муса әфәнденең пәйгамбәр хәдисләрендә телгә алынган динне яңартучылардан булуын таныган: «*Муса Бигиеф әфәнде соңгы заманнарда зоһур иткән*[2] *дине ислам мөҗәддидләреннән бередер*».

Алга таба Мостафа Сабри болай дип язган: «*Мөселманларның хәбәре булып торсын өчен дин исляхчыларыннан исламияткә зарар килү ихтималы хакындагы борчылуларыбызда, вәсвәсәләребездә ике сәбәп белән мәгъзүрбез:*

*Әүвәлән болар, борынгы мокътәда биһиләрне*[3] *ислам карашында бәреп төшертеп, алар урынын үзләрен алырга телиләр… исляхҗиләр вакытында ислам диненә тиешенчә хезмәт иткән әсляф голәманы*[4] *дә, аларга мәнсүб улдыгы*[5] *бөтен ислами голүмнәрне дә аяклар астына аталар. Бакыңыз Казанлы Муса Бикийеф әфәнде нә дийюр…*»[6].

Әлеге җөмләләрдән аңлашылганча, Сабри әфәнде Муса Бигиевнең һәм аның кебекләрнең мөселман җәмгыятен артта калганлыктан чыгару өчен куйган тырышлыкларын күрмичә яки күрергә теләмичә, бәлки аларның бу юнәлештә әйткәннә-

---

ларак, аның авторы күрсәткән юлларның ялгыш булуын күрсәтеп, ул китапның эчтәлеген дөрес аңлауда бер раһбәр (әйдәп баручы) сурәтендә язган.

[1] Ягъни: Казанлы Муса Бигиев әфәнденең кәлям гыйлемебез хакындагы яман фикерләре.

[2] Зоһур иткән – килеп чыккан; күренгән.

[3] мокътәда биһи – үзенә ияртеп баручы; раһбәр, лидер.

[4] әсляф голәма – борынгы заманның сәләфләре, ягъни чын мәгънәдә диндар, игелекле, пакь, тәкъвалы галимнәр.

[5] мәнсүб улдыгы – бәйле булган.

[6] Сабри. Дини мөҗәддидләр, б. 9–10. (госманлы теленнән тәрҗемә ителде).

ре-язганнарының эчтәлегенә төшенеп тә тормастан, ярсуын яшермичә, борынгы авторитетларны бәреп төшерергә тырышуда гаепли. Аерым алганда, Сабри әфәнде Муса әфәндедәнең гыйлеме кәлям исемле дини дисциплинага һөҗүм итүен күтәрә алмый һәм әсәренең зур өлешен гыйлеме кәлямдәге тәгълиматларны һәм кәлямчы галимнәрне яклауга багышлый. Чыннан да, Муса әфәнде кәлям гыйлемен һәм аны буш урында барлыкка китереп үстергән борынгы галимнәрне ифрат сурәттә нык тәнкыйтьләп, мөселманнарның акылын сүндерүдә, дөньяга карашларын чикләүдә, фикер үсешен туктатуда, иманнарын бутап-чуалтып рухларын гарипләүдә гаепләгән. Әмма болай иткәндә, Муса әфәнде кәлям гыйлеменең ислам тәгълиматы өчен ят, ясалма, бармактан суырып чыгарылган бер дисциплина булуын ассызыклый. Сабри әфәнденең кәлям гыйлеменә карашы бөтенләй башка була. Ике фикер иясенең бу бәрелешләрендә чын мәгънәдә кадимчелек белән, ягъни борынгы калыпларга ябышып ятуны алга сөргән яшәеш фәлсәфәсе белән, мөҗәддидлек фәлсәфәсе, ягъни үзгәреп торган дөньяда диннең әлегә кадәр кулланылмыйча яткан көчләрен, мөмкинлекләрен файдалануны күздә тоткан агымнар бәрелешә.

Шуны да әйтергә кирәк ки, Сабри әфәнде Муса Бигиевнең тирән дини гыйлемгә ия, ислам диненә ихластан бирелгән булуын таный. Шул сәбәпле ул аны Көнбатыш галәмәтләренә мөкиббән китеп, ислам динен хурлап, тамырына балта чабып юкка чыгарырга теләгән *фәрангичелеләрдән*, ягъни Көнбатышка һәм аның казанышларына табына башлаган интеллигенция вәкилләреннән аера, андыйлар белән бер сафка куймый. Ул гына да түгел, Мостафа Сабри әфәнде Муса Бигиевнең дингә, аерым алганда, кәлям гыйлеменең мөселманнарга ясаган тискәре йогынтысы турындагы фикерләре белән ризалаша алмавына карамастан, татар галименең ислам дөньясында дин хакында бәхәстәш була алырлык бердәнбер галим булуын ачыктан-ачык таный торган булган. Бу турыда Йосыф Уралгирәйнең хатирәләреннән укып беләбез: «*Муса әфәнденең тәнкыйтьчесе Сабри әфәнде, Муса әфәнде-*

*не бер мөҗтәһид буларак кабул итсә дә, 1912-ләрдә кайбер фикерләрен чиктән ашкан дип тапкан. Фәкать бу тарихтан 30 яки аннан да күбрәк еллар үткәннән соң, гарәп галимнәре белән дә, алардан соң шәхсән үз вәкиле Кәүсәри хуҗа белән дә бәхәсләшкәндә еш кына «үзе белән сүз тартышырлык бердән бер галим Муса Җаруллаһ әфәндедер», дип әйтә иде»*[1].

Киләчәктә Муса Бигиевнең идеяләре белән Мостафа Сабри әфәнденең фикерләрен үзара чагыштырып, бер яктан, татар галименә каршы алып барылган кадимчел һөҗүмне, икенче яктан, Муса әфәнденең дәлилләрен һәм фикерләрен галимнәребез игътибар үзәгенә куеп тикшерерләр дигән өметтә калам. Әгәр бу эш барып чыкса, ул тикшеренү нигезендә гаҗәеп тирән эчтәлекле бер фәнни хезмәт язылып, төрки халыкларда дин фәлсәфәсенең дә, дини фәлсәфәнең дә тиңдәшсез дәрәҗәдә югары булуы күрсәтелеп, татар иҗтимагый фикере тарихын нык баетыр иде.

## Әнвәр-паша белән танышуы һәм Шәрык халыкларының Беренче корылтае

1920 елның март аенда Муса әфәнде һәм аның белән бергә Габдерәшит казый һәм Мәүләви Бәрәкәтуллаһ Башкортстанга барып чыгалар. Анда алар Башкорт Республикасының Вакытлы хәрби-революцион комитеты рәисе урынбасары һәм хәрби эшләр буенча халык комиссары булып эшләгән Әхмәт-Зәки Вәлиди белән күрешәләр. Бу күрешү турында Зәки Вәлиди болай дип язган: «*Ошбу хөрмәтле кешеләр Башкорт милли хөкүмәтенең кунаклары иделәр. Анда без аларга кадер-хөрмәт күрсәттек һәм киләчәктә алар моның өчен һәрвакыт шөкер кылалар иде*»[2].

---

[1] Yusuf Uralgiray. Önsöz. Filozof Musa Carullah Bigi. Uzun Günlerde Oruç. İctihad Kitabı. Eseri sadeleştirerek dipnotlara işleyen Yusuf Uralgiray. Ankara, 1975. S. XXV. (Алга таба: Uralgiray. Önsöz).

[2] Заки Валиди Тоган. Воспоминания. Борьба народов Туркестана и других восточных мусульман-тюрков за национальное бытие и сохранение культуры. Книга I. Уфа: «Китап», 1994. С. 344.

Күптәнге танышлары һәм остазының нинди кыен хәлдә калуын күргән Вәлиди Муса әфәндене Башкорт Республикасы юстиция ведомствосы буенча киңәшче итеп билгели[1]. Бу тоз сатып көн күрүгә калган олуг галимгә транспортта ил буйлап бушлай йөрү мөмкинлеген бирә. Аңарчы китапларын сату исәбенә яшәгән Муса әфәнде бу елларда андый мөмкинлеген югалта: ни китаплары басылмый, ни аларны күпләп сатып алучы сәүдәгәрләр булмый. Форсаттан файдаланып, Вәлиди кунакларына исламны коммунизм белән тиңләштерүдән ваз кичәргә һәм советлардан ярдәм сорыйсы урынга бер мөмкинлек килеп чыгу белән шундук илне ташлап китеп, берәр ислам иленә һиҗрәт кылырга киңәш итә.

Ул арада 1920 елның язында Мәскәүгә күренекле госманлы дәүләт эшлеклесе, маршал, хәрби министр, сәясәтче Әнвәр-паша килеп төшә. Башкортстаннарда йөреп Мәскәүгә әйләнеп кайткан Муса әфәнде паша белән шул ук елның җәендә шәхсән таныша[2] һәм бу танышлыкның беркадәр дәвамы да була.

Әнвар-паша фигурасына килгәндә, аның үзе турында да, Госманлы иле тарихына керткән өлеше, Беренче бөтендөнья сугышыннан соңгы сәясәт мәйданында тоткан урыны, сугыш нәтиҗәсендә биләмәләренең күпчелеген югалткан Төркиянең язмышына карата корган планнары һәм, ниһаять, совет Русиясенә килеп башта большевиклар белән уртак максатлар табуы, аннары аларга каршы Төркестан мөселманнарын сугышка күтәрүе хакында да озак сөйләп булыр иде[3].

---

[1] Заки Валиди Тоган. Шунда ук.

[2] Баруди Г. Хатирә дәфтәре: 1920 елның 12 июненнән алып сентябрь ахырына кадәр / Басмага әзерләүче А. Гайнетдинов.– Казан: ТР ФА Ш. Мәрҗани исемендәге Тарих институты, 2017. Б.176–177.

[3] Әнвәр-паша (Исмәгыйль Әнвәр-паша, 1881–1922) – Госманлы дәүләтенең хәрби эшлеклесе, 1909 елдан Алманиядә хәрби атташе; сәясәтче, 1908 елда Яшь төрекләр башлаган инкыйлабта актив катнашучы, «Иттихад вә тәрәккъый» сәяси партиясенең җитәкчеләреннән берсе; Җиһан сугышы вакытында Госманлы дәүләтенең хәрби министры. 1913 ел башында Әнвәр-паша Кямил-паша хөкүмәтенең егылуына китергән инкыйлаб (түнтәрелеш) оештыра һәм илдә Тәлагать-паша (1874–1921), Җәмал-паша (1872–1922) һәм үзеннән

Әнвәр-паша һәм аның сәяси тарафдарлары белән большевиклар арасында килешүгә ирешү мөмкинлеге барлык-

---

гыйбарәт булган «Өч паша» (Триумвират) хәрби диктатурасын урнаштыра. Җиһан сугышы башлангач (1914), Әнвәр Төркиянең Алмания белән хәрби бердәмлеге тарафдары булып, илнең сугышка Алмания тарафында катнаша башлавы өчен көч куя. 1914 елның декабрь – 1915 елның гыйнвар айларында Әнвәр-паша Көньяк Кавказда Русиягә каршы Сарыкамыш һөҗүмен башлый, әмма ул бәрелештә 70–90 мең төрек солдаты һәм офицерлары һәлак булып, 15–66 меңгә кадәре әсир ителеп, Әнвәр-пашаның һөҗүме уңышка ирешми. 1918 елны Мудроста, Төркия вакытлы солых килешүен имзаланганнан соң, Әнвәр-паша, Тәлагать-паша һәм Җәмал-паша Алманиягә качып китәләр. Шулай да, 1919 елда Госманлы Дәүләти Галиясендә Әнвәр-пашага каршы хәрби трибунал башланып, ул хәрби җинаятьләре өчен үлем җәзасына хөкем ителә. Мондый шартларда Әнвәр-паша үзенә яңа союздаш көч эзләргә мәҗбүр була һәм 1919 елда Алманиядә Совет Россиясенең вәкиле күренекле коммунист Карл Радек (1885–1939) белән күрешә. Большевиклар үзләренең сәяси программаларында Русия хөкүмәтен Җиһан сугышында җиңелүгә китерү буларак теркәлгән планны үтәү йөзеннән, инде 1914–1917 елларда ук, искә алынган өч паша һәм Әхмәт бәк Агаевлар тарафыннан алга сөрелгән «Туран юлы» дип аталган һәм Кавказда, Иранда, Кырымда, Идел-Уралда һәм Төркестанда яшәгән төрки халыкларны Бөек Туран чикләрендә берләштерүне күздә тоткан сәяси проектны хуплап, яшерен сурәттә теләктәшлек күрсәткән булалар. Радек белән күрешеп сөйләшкәннән соң, Әнвәр-паша совет большевиклары белән рәсми элемтә һәм мөнәсәбәтләр корырга карар кыла. Максаты алман хәрби даирәләре белән большевикларны килештереп, аларның ярдәме белән, Төркестанда Бөекбританиягә каршы зур сугыш башлау була. 1920 елның язында Әнвәр-паша үзенең көрәштәшләре белән Мәскәүгә килеп төшә, РСФСР хөкүмәте чакыруы белән Бакуда 1–8 сентябрьдә үткәрелгән Шәрык халыкларының Беренче корылтаенда катнаша. 1921 елның көзендә большевиклар, басмачыларны берләштертү өчен, аны Төркестанга җибәрәләр. Әмма большевикларның Төркестанда ниләр кылганын күреп, Әнвәр-паша җирле халыкны һәм партизан хәрәкәтендә катнашкан кораллы көчләрне (басмачыларны) Совет хакимиятенә каршы сугышка күтәреп, 1922 елда Кызыл Армия гаскәре белән бәрелешләрнең берсендә 4 августта һәлак була.

ка килгәч, ул киләчәккә караган максатларны күздә тоткан программасын бәян итә: 1. Мөселман милләтләрен азат итү. 2. Империалистик капитализм мөселманнарның да, социалистларның да дошманы булганга күрә, социалистлар белән хезмәттәшлек итү. 3. Әгәр социализм мөселман тормышының эчке үзенчәлекләрен тәртипкә салган дин хөкемнәренә яраклаша алса, аңа кушылу. 4. Исламны азат итү өчен басым ясарга яраклы һәр чараны, шул исәптән, революцияне дә файдалану. 5. Бу юлда буйсындырылган гайре мөселман милләтләр белән хезмәттәшлек итү. 6. Ислам җәмгыяте эчендә һәр иҗтимагый катламга үсеш мөмкинлекләрен тапшыру.

Әлеге программа Муса әфәнденең карашларына бик якын булганга күрә, ул Әнвәр-пашага, аның Шәрык халыкларын азат итүдә уйный алырлык роленә, әлбәттә, зур өметләр баглаган була дип уйларга нигез бар. Әмма Шәрык сәясәтендә большевиклар тарафына Әнвәр-пашаны җәлеп итү планнары булсын, Муса әфәнденең абруен куллану булсын – боларның барысы артында да Троцкийның большевиклар революциясе ялкынын Шәрык җирләрендә, беренче нәүбәттә Фарсыстанда кабызып җибәрү нияте яткан була. Нәкъ менә шушы стратегик максатны күздә тотып, революцияне чит илләргә күчерү юлларын табу өчен, 1920 елның 1–8 сентябрендә Бакуда Шәрык халыкларының беренче корылтае үткәрелә дә инде[1].

Шәрык халыкларының беренче корылтаена өч дистә илдән җыелган ике меңгә якын делегатның рухи күтәренкелеге шулкадәр дәрәҗәгә җитә ки, корылтайны оештыручыларның берсе буларак минбәрдән чыгыш ясаган большевик Г. Зиновьев[2] ялкынлы нотыгын сөйләгәндә, әллә кызып китеп, әллә алдан уйланылган планны үтәп, Антантага каршы изге сугыш, ягъ-

[1] Муса әфәнденең бу чарада катнашуы-катнашмавы әлегә билгеле түгел, әмма аның тормышында 1920 ел дәвамында булган вакыйгаларның хронологиясе бу катнашуның, һәрхәлдә, мөмкин булуына каршы килми. Тик моны раслый торган катгый документаль дәлилләр әлегә табылмады.

[2] Г. Зиновьев (Овсей-Герш Аронович Радомысльский; 1883–1936) – революционер, совет сәясәт һәм дәүләт эшлеклесе. Репрессияләнгән.

ни җиһад игълан иткән мәлдә, барлык делегатлар урыннарыннан сикереп торып бу сөрәнне алкышлап каршы алалар: «*Братья, мы призываем вас к священной войне прежде всего против английского империализма! (Буря аплодисментов, долгие крики «Ура». Члены съезда встают, потрясая оружием. Оратор долго не может продолжить. Все… стоят и аплодируют. Крики: Клянёмся!»*[1]

Зиновьев әйткән бу сүзләрне халык чынлап та җиһад башлау буларак кабул итә. Моның шулай булуын ул корылтайда катнашкан Брагинскийның[2] хатирәләре раслый: «*Залда сурәтләү мөмкин булмаган бер хәл булды. Җавап йөзеннән телләрнең һәммәсендә газават турында, изге сугыш турында, революцион восстание турында кычкырулар яңгырады. Бүрекләрен, фәсләрен, чалмаларын, түбәтәйләрен өскә чөйделәр, кавказлылар хәнҗәрләрен зыңлаттылар, калганнары кызыл тукымалар болгадылар: «Газават!»»*[3]

Бу дулкынландыргыч манзарадан тәэсирләнгән К. Радек озакка сузмыйча матбугат сәхифәләрендә корылтайның, аның фикеренчә, иң мөһим мизгелен сурәтләп, түбәндәге хатирәләре белән уртаклаша: «*Никто из участников съезда не забудет момент, когда на призыв Зиновьева к священной войне против мирового империализма две тысячи делегатов поднялись, как один, выхватили револьверы и сабли, и клялись бороться до последней капли крови против своих поработителей»*[4].

Ул көннәрдә совет власте җиһад кадәр җиһад игълан итәрлек хәлдә булганда, ул, әлбәттә, Муса әфәнде кадәр танылган ислам рәһбәрен үз мәнфәгате өчен файдаланудан баш тарт-

[1] Рубен Саакян. Первый съезд народов Востока. С. 37–66.

[2] Брагинский (Израэли-Йосыф Самуилович Брагинский; (1905–1989) – совет шәркыятьче галиме, әдәби тәнкыйтьче, әдәбият белгече, Төркестан, Урта Азия һәм Иран мәдәнияте һәм таҗик-фарсы әдәбияты тарихы буенча хезмәтләр авторы, филология фәннәре докторы.

[3] Файн В. Я. Жизнь востоковеда. Б.37.

[4] Радек К. Съезд народов Востока // Знамя революции. Томск, 23 сентября 1920 г., № 203.

мас иде һәм, мөгаен, файдаланган да. Хөкүмәтнең Шәрык сәясәтенә карата планнарының нинди булуын Муса әфәнде, шөбһәсез, белеп торган һәм үзе дә эшчәнлегендә моны исендә тотып хәрәкәт иткән. Моның чыннан да шулай булуы аның 1920 елның 16–18 сентябрендә Уфада үткәрелгән Бөтенрусия ислам руханиларының корылтаенда катнашканда ясаган чыгышларының кыюлыгыннан һәм сәясәт кырында куркусыз эшчәнлегеннән дә сизелә. Бу корылтайда, Зыяэтдин Кәмали һәм Кырым мөфтие Ибраһим әфәнде белән киңәшләшкәннән соң, Муса әфәнде корылтай исеменнән Русия мөселманнарының хәлифәгә буйсынулары турында рәсми игълан ясый. Мондый масштаблы сәяси чаралар минбәреннән Муса әфәнде аңа власть кушкан нәрсәләрне сөйләгән дип аңларга, әлбәттә, ярамый. Власть ул заманда Муса әфәндегә теләгәнен әйтергә комачауламаган. Муса әфәнденең шул ук корылтайда һич курыкмыйча диндәшләрен үзе язган һәм Русия мөселманнарын гына түгел, бөтендөнья мөселманнарын да үз эченә алган ислам конституциясе проекты белән таныштыруы ул көннәрдә хөкем сөргән сүз һәм фикер ирегенең тагын бер чагылып торган мисалы булып тора. 1920 елда ул бу әсәрен Төркестан, Әфганстан, Төркия, Финляндия матбагаларының берсендә бастырып, ислам мәмләкәтләренә таратырга ниятләгән булса да, моны булдыра алмаган, әмма Советлар илендә үткәрелгән мөселман корылтаенда аны тәкъдир итә алган. Сүз «***Исламийәт әлифбасы***» дип аталган ислам сәяси программасы турында бара. Бу хезмәт бары тик 1923 елда Берлинда «***Ислам милләтләренә дини, әдәби, сәйәси мәсьәләләр, тәдбирләр хакъкында***» исемле китап буларак басылып чыга. Аны алга таба әле искә алырбыз.

## Бохара белән Ташкентта. Беренче тоткарлану

Ул арада совет хөкүмәте белән килешү корып, Мәскәү кубызына биюдән баш тарткан Бохара әмиренең биләмәләренә 1920 елның 2 сентябрендә Кызыл Армия һөҗүм итә һәм Бохара әмирлеген яулап алып, 1911 елдан бирле хакимлек ит-

кән Сәед Галимхан[1] әмирне тәхеттән бәреп төшерә. Кызыл Армия белән союздашлык кылган җирле таҗик һәм үзбәк большевиклары Бохара Халык Шура Җөмһүрияте (Бохара Халык Совет Республикасы) оештырылуын игълан итәләр. Мондый вакыйга, әлбәттә, Муса әфәндене игътибарын җәлеп итми калмый һәм, Уфадагы корылтайдан соң, ул Бохарага юл тота. Борынгы шәһәргә барып төшкәч, Муса әфәнде большевиклар гаскәренең нинди зур вәхшилекләр кылганын үз күзләре белән күрә һәм бик авыр хисләр кичерә. 1935 елда Каһирәдә гарәп телендә язылып дөнья күргән «***Әл-Вәшигату фи нәкъди гакаъиди әш-шигати***» исемле китабында Бохарада күргәннәре турында ул мондый сүзләр язачак: «*1920 елның ахырларында Бохара үз угылларыбыздан торган гаскәри бер куәт – большевиклар явына дучар булганнан соң шунда киттем. Бу гаскәр бу җирләрне һәм басып алган, һәм ничәмә-ничә гасыр дәвамында биредә җыелып килгән кыйнтар-кыйнтар хәзинәләрне һәм бихисап байлыкларны талап алып, үзләренең поездларына төяп башкалаларына озаттылар (бу санап бетергесез байлыклар әле һаман да аларның көч-куәтләренә нигез булып тора). 1920 елның ахырларында Бохарага бардым. Күргәннәрем ифрат та куркыныч иде: иң матур мәдрәсәләр йә базар бәдрәфләре урынына, йә ишәк абзарлары урынына кулланыла иделәр! Хәсрәтләнүем шундый дәрәҗәгә җитте ки, биредә нибары өч көн тора алдым һәм өч көн үтү белән аннан башымны алып качтым*»[2].

Хәрабә хәленә китерелгән Бохарадан Муса әфәнде Ташкентка юл тота һәм Йуныс-хан мәдрәсәсенә мөдәррис булып урнаша, башы белән эшкә чумып, яңа 1921 елны шунда каршылый.

1921 елның 28 мартында һаман да шул Йуныс-хан мәдрәсәсендә мөдәррис булып эшләп торган Муса әфәнде күренекле революционер большевик Н. И. Бухаринның (1988–

---

[1] Сәед Галим хан (Сәет Мир Мөхәммәд Галим-хан; 1880–1944) – Бохара әмирлегенең соңгы (12-нче) хөкемдары.

[2] Муса Җаруллаһ. Әл-Вәшигату фи нәкъди гакаъиди әш-шигати. Каһирә: Матбагату әл-Киляни. Б. 24.

1938) мәсләктәше Е. А. Преображенский (1886–1937) белән бергә язып, 1920 елда дөньяга чыгарган «*Азбука коммунизма*» исемле китабына җавап буларак, 1923 елда басылып чыгачак ***«Ислам милләтләренә дини, әдәби, сәйәси мәсьәләләр, тәдбирләр хакъкында»*** (***«Исламийәт әлифбасы»***) китабының күләмле кереш сүзен тәмамлый. Әлеге кызыклы тарихи-сәяси документның татар теленә тәрҗемә ителгән бер өзеге белән кушымтада танышырга мөмкин[1].

Ул чакта Ташкент һәм аның әйләнә-тирәсендәге җирләрдә сәяси вазгыять гаять киеренке була. Совет власте Ташкентта кораллы восстание нәтиҗәсендә 1917 елның октябрь ахырында ук урнаштырылып, РСФСРның бер өлеше булган Төркестан совет җөмһүриятенең (ТСҖ) барлыкка китерелүен игълан итә. Бу хәл белән ризалашырга теләмәгән көчләр Советларга каршы партизан хәрәкәте башлыйлар. Өстәвенә, җирле большевистик хакимият вәкилләре арасында да совет властена каршы көч була. Мәсәлән, 1919 елның гыйнварында РКП(б) әгъзасы ТСҖ хәрби комиссары К. Осипов һәм аның кебек үк башка большевиклар җирле Совет власте органнарына каршы кораллы восстание башлыйлар. Гыйсьянчылар җирле хакимият вәкилләреннән 35 кешене атып үтерәләр һәм казнаны урлыйлар. Бу гыйсьян уңышка ирешмәсә дә, ул вакытта Төркестан совет җөмһүрияте тынычлык вә иминлекнең ни икәнен белми – биредә чын мәгънәдә гражданнар сугышы бара, совет тарих фәнендә басмачылык дип аталган милли-азатлык өчен көрәш көчәя.

Мондый шартларда Муса әфәнденең Ташкентка килүе һәм биредәге эшчәнлеге, дус-ишләре һәм фикердәшләре белән очрашулары җирле иминлек хезмәтенең, ягъни Ташкент шәһәренең ЧК хезмәткәрләренең игътибарын җәлеп итми кала алмый, әлбәттә. Шуңа күрә 1920 елның март аенда Муса әфәнденең һәм аның белән бергә тагын берничә дистә җирле мөселман активисты һәм җәмәгать эшлеклесенең кулга алынулары сәер булып күренми. Аерым алганда, Муса әфән-

[1] Карагыз: III Бүлек. 13: «Дини мәктәбләр, мәдрәсәләр хакында төзүченең мөляхәзалары».

де Төркестанда эшчәнлек алып барган «Иттихад миллия»[1] исемле сәяси оешмада катнашуда гаепләнә. Бу турыда сорау алу протоколларында ул болай дип язган: «*В конце 20-го года я поехал в Туркестан, остался там до конца марта 21 года, приготовился обратно ехать к своей семье, был арестован Ташчекой, сидел 50 дней, мое дело было прекращено следствием, меня освободили, взяли подписку не бросать Ташкент, остался там до конца сентября*».

Озакка сузылган тикшерү дәвамында Муса әфәнде ике айга якын вакытын авыр зиндан шартларында үткәрә. Нинди дә булса гаебе табылмавы сәбәпле, җәй башында аны зинданнан чыгаралар, әмма Ташкенттан китәргә рөхсәт бирмиләр. Нәтиҗәдә, Ташкенттан китмәячәге турында подписка язган Муса әфәнде сентябрь аеның ахырына кадәр шунда калырга мәҗбүр була.

Ташкент төрмәсендә утырган көннәрдә Муса әфәнде Әнвәр-пашага берничә хат яза. Әлеге документларны Әнкарада үткәргән тикшеренү экспедициясе вакытында табарга насыйп булды. Моңа берничә сәбәп була: беренчедән, Әнвәр-пашаның ул чакта Мәскәү хакимияте белән дустанә мөнәсәбәттә булуын белгән Муса әфәнде аңардан үзен һәм аркадашларын төрмәдән азат иттерү өчен ярдәмен үтенә. Икенчедән, Әнвәр-пашага Төркестандагы вазгыять турында тирән эчтәлекле күзәтү тәкъдим итә, биредә сәяси эшчәнлекнең перспективалары белән таныштыра һәм башка бик күп мәгълүмат җиткерә. Муса әфәнденең ул чакта Әнвәр-пашаны әле һаман да большевиклар белән әшнәдер дип уйлаганы аңлашыла, бу госманлы генералның мөселманнарны җитәкләп большевиклар белән бергәлектә империализмга һәм колониализмга каршы көрәшкә күтәрә алачагына нык ышанган булуы ярылып ята. Ул хатларның берсен китапның кушымтасында урнаштырдык[2].

---

[1] Иттихад миллия (Милли иттихад) – совет тарих фәненең бәяләмәсендә 1919–1923 елларда Төркестан республикасында эш иткән милли-контрреволюцион оешма.

[2] Карагыз: III Бүлек. 14: Муса Җаруллаһның Әнвәр-пашага язган хаты.

## Исмәгыйль Сойсаллы һәм «Төркия бөек милләт мәҗлесенә мөрәҗәгать»

Төрмәдән чыгарылып та Ташкентта калырга мәҗбүр булган көннәрдә Муса әфәнде Русиягә рәсми зиярәт белән килгән Төркия делегациясе вәкиле, парламент депутаты Исмәгыйль Сойсаллы[1] әфәнде белән таныша.

Совет Русиясенә Мостафа Кәмал җитәкчелек иткән Төркия революцион хөкүмәтеннән бу кадәр дәрәҗәле вәкилләр килүе Мәскәүнең, Әнвәр-паша белән араларын өзеп, симпатияләрен аның көндәше булган һәм киләчәктә лаеклы сурәттә Ататөрек исеме белән аталачак Мостафа Кәмалга бәйләүләрен күрсәтә. Моның нәтиҗәсендә үзенә һәлакәт янаганын Әнвәр-паша, әлбәттә, аңлый һәм шуңа күрә Бакудагы съезддан яшерен рәвештә качып, эзләрен бутап, Хәзәр (Каспий) диңгезе аша Төркестанга килеп төшә һәм биредә, Муса әфәнденең хатында курбашилар дип аталган басмачыларны берләштереп, аларны җирле совет хакимиятенә каршы сугышка күтәрә.

Аңарчы Петроград, Мәскәүләрне күреп, Идел-Урал төбәкләрендә Казан, Оренбургларда йөргәндә андагы хәлләр белән якыннан танышкан делегация әгъзалары 1921 елның ул көннәрендә, Төркестанга килеп, Ташкент белән Бохарадагы хәлләр белән танышалар. Бу турыда да Муса әфәнде протоколларда язып калдырган: «*Летом приехал туда* [Ташкентка,– А.Х.] *член комитета по изучению России – член Великого Национального Собрания Турции Исмагил Субхи Сойсаллы. Он знал меня раньше по моим трудам и может быть потому, что часто заходил ко мне в медресе, где я жил и мударрисом которого я назначен и где я занимался преподаванием Корана. Только он мог достаточно познакомить с положением революционной Турции.*

---

[1] Исмәгыйль Сойсаллы (Исмәгыйль Субхи Сойсаллыоглу; 1884–1967) – төрек сәясәтчесе, Истанбул Хокук институтын тәмамлаган; прокуратурада эшләгән, «Сәрвәте фөнүн», «Шураи өммәт», «Икдам» кебек матбугат чараларында эшләгән. I Төркия Бөек Милләт Мәҗлесенең Бурдур халык депутаты (1920–1923).

*Я – человек мало говорящий в своих беседах, старался слушать его, а он любил говорить, только поэтому мне удалось пользоваться его знаниями. Такими удачными случаями я познакомился с положением в Турции и решил использовать Исмагил-Субхи в моем обращении*[1].

*Турки – очень честные и очень убежденные мусульмане. Только поэтому я дал себе, как носителю Корана, право давать какие нибудь советы по разным вопросам жизни и даже политике, так как Коран очень ясно и очень правильно дает свое учение и строгие повеления по каждому вопросу жизни и политики».*

Исмәгыйль әфәнде Сойсаллыга килгәндә, ул Муса әфәнде турында аңарчы ишетеп тә белгән, китапларын да укып, аның фикер дөньясы белән танышып өлгергән була. Төркиядән килгән мәртәбәле кунак белән аралашкан чагында Муса әфәнде аның сөйләгәннәреннән кискен һәм тирән үзгәрешләр кичергән Төркиядәге сәяси вазгыять турында мөмкин кадәр күп хәбәр алып калырга тырыша. Сойсаллы авызыннан Төркиядәге хәлләр белән танышуы нәтиҗәсендә, Муса әфәнде үзенең «***Төркия бөек милләт мәҗлесенә мөрәҗәгать***» («***Мөрәҗәгать***») исемле мәшһүр һәм гаять үзенчәлекле бер әсәрен яза һәм аны Сойсаллыга тапшырып, Төркия парламенты депутатлары хозурында яңгыратуын үтенә. Бу мөрәҗәгатендә Муса әфәнде илне яңа тарихи-цивилизацион юлларга чыгарга тырышкан Төркия хөкүмәтен, дәүләт эшлеклеләрен ислам дине хөкемнәренә таянып эш итәргә үгетли, дөньяда барган тарихи, сәяси, иҗтимагый, мәдәни процессларга үзенең карашын һәм уй-фикерләрен бәян итә һәм, Төркиянең җанатары буларак, бу илнең нык киләчәген тәэмин итәрлек адымнар тәкъдим итә. Исмәгыйль әфәнде бу «*Мөрәҗәгать*»не үзе белән иленә алып китә, әмма ул, ниндидер сәбәпләр аркасында, Төркия парламенты депутатлары алдында укылмый, гәрчә Сойсаллы Русияне зиярәт итүләре турында анда махсус чыгыш ясаган булса да. Шулай да, Исмәгыйль әфәнде «Мөрәҗәгать»не Төркия Бөек Милләт Мәҗлесе (ТБММ)

[1] «Төркия Бөек Милләт Мәҗлесенә мөрәҗәгать» күздә тотыла.

рәисе Гази[1] Мостафа Кәмал әфәндегә күрсәткән булган, әмма аның бу документка карата кызыксыну белдермәве сәбәпле, Сойсаллы аны аны кире алган[2]. «*Мөрәҗәгать»* шулай ук Төркия парламенты депутатлары хозурында да укылмаган. Бу Исмәгыйль Сойсаллының, Русиядән ватанына кайтып, Бөек Милләт Мәҗлесе утырышларында ясаган чыгышлары белән танышканнан соң билгеле булды. Шундый чыгышларның берсендә ул, Идел-Урал төбәкләрендә хөкем сөргән коточкыч ачлык турында доклад ясап, коллегаларын ачлыктан интегүче татар, башкорт, казакъ, кыргыз мөселманнарына, бигрәк тә аларның балаларына ярдәм итү чараларын табарга өнди[3]. Икенче бер чыгышында Русиядәге сәфәреннән аңа бүләкләр рәвешендә бирелгән 700 том китаплар һәм 1914–1915 елларда Кавказ фронтында рус армиясенә әсир төшеп, Красноярскида тоткыннар лагеренда интеккән төрек сугышчылары кулъязма сурәтендә чыгарган «Vaveylâ» исемле гыйльми, әдәби, юмористик атналык газетаның Русиядән алып кайткан коллекциясе турында белдерү ясый. Әмма Сойсаллының бу чыгышларының берсендә дә Муса әфәнденең «*Мөрәҗәгате»* турында һичнәрсә әйтелми[4].

Хәзерге вакытта «*Мөрәҗәгать»*нең оригиналь кулъязмасы кайда булуы билгеле түгел. Кайбер чыганакларга карaганда, ул 1931 елда Каһирәдә басылып чыккан, тик бу басма да әлегә кадәр табылмады. Бәхетебезгә, бу әсәрен Муса әфәнде Лубянка төрмәсендә утырганда следствие таләбен үтәп үз

---

[1] Гази (дин өчен канын фида кылган ислампәрвәр кеше) – әлеге мактаулы исем Мостафа Кәмал әфәндегә ТБММ тарафыннан 1921 елның сентябрь аенда бирелә.

[2] Battal-Taymas. Күрс.хезм., s. 57.

[3] T.B.M.M. Zabıt Ceridesi. Cilt 18. 1 Mart 1338 tarihli Birinci İçtimadan 4 Nisan 1338 tarihli Yirminci İçtimaa kadar. Ankara: T.B.M.M. Matbaası, 1959. S. 479.

[4] T.B.M.M. Zabıt Ceridesi. Cilt 19. 6 Nisan 1338 tarihli Yirmi Birinci İçtimadan 6 Mayıs 1338 tarihli Kırkıncı İçtimaa kadar. Ankara: T.B.M.M. Matbaası, 1959. S. 359–360.

кулы белән урыс теленә тәрҗемә иткән булган. Ул тәрҗемәне укучылар игътибарына кушымтада тәкъдим итәбез[1].

## Петроградта иҗтимагый эшчәнлек

Совет хакимияте астында яшәвен дәвам иткән Муса әфәнде совет хөкүмәтенең, большевикларның башбаштаклыкларын күреп, мөселманнарга карата булган мөнәсәбәтнең тискәреләнүен үз өстендә дә «татый». Шундый күңелсез хәлләрнең берсе Муса әфәнденең Петроград Җәмигъ мәчете мәхәлләсендә алып барган эшчәнлеге белән бәйле. 1921 елның көзендә Петроградтагы бер дәүләт учреждениесе Петроград Җәмигъ мәчете каршындагы мәхәлләнең (обществоның) регистрациясен яңартуын таләп итә. Әлеге мәхәлләнең активын тәшкил иткән шәхесләр, шул исәптән Муса әфәнде Бигиев, Мөхәммәт-Галим әфәнде Максутов, Лотфулла хәзрәт Исхаковлар эшкә тотыналар һәм тиз арада Петроград Җәмигъ мәчете каршындагы мөселман оешмасының Уставын язып чыгып, тиешле булган башка документларны әзерләп тапшыралар. Уставта мөселман активистларының ислам дине кагыйдәләрен Совет власте алга сөргән хөкемнәр һәм таләпләр белән үзара яраклаштырырга тырышулары сизелеп тора. Әлеге мөселман оешмасы 1921 елның 8 октябрендә регистрацияләнә. Әмма озак та үтми, Петроград шәһәре милләтләр комиссариатының татар бүлеге мөдире Рәхимов, Җәмигъ мәчет мәхәлләсе идарәсенә һәм аның эшчәнлегенә яла ягып, югары инстанциягә донос сурәтендә бер гариза яза. Нәтиҗәдә идарә әгъзалары дин эшләре белән шөгыльләнүче дәүләт органына чакыртылалар, алар белән сорау алу сыман кырыс бер әңгәмә үткәрелә һәм алып барган эшчәнлекләрен нык чикли торган подпискалар алына. Муса әфәнде биргән подпискада мондый сүзләр бар: «*Я, нижеподписавшийся священник церкви мухаммеданского храма Муса Джарулла Бигеев, поставлен в известность завед. Церковным столом Ивановым, что беседы, а равно и другие какие-либо сборища помимо церков-*

[1] Карагыз: III Бүлек. 15: «Обращение к Великому Турецкому Национальному Собранию».

*ных служб без разрешения завед. указанного стола обязуюсь устраивать, предварительно подав заявление за трое суток. Сборища, собранные без разрешения, будут приравниваться к нелегальным, а потому нести за указанное заслуженную кару по всем строгостям законов Российской Социалистической Федеративной республики.*

*М. Бигеев, 12 декабря 1921 г.»*

Әмма монысы гына аз була, чөнки 13 декабрьдә Петроград Җәмигъ мәчете каршындагы мөселман оешмасы хөкүмәт органнары карары белән рәсми рәвештә юк ителә[1]. Әмма хәлләр начарайганнан-начарая барса да, Муса әфәнде боекмый, булдыра алган кадәр үзенең иҗтимагый эшчәнлеген дәвам итә һәм яңа хакимият белән килешеп эшләү юлларын табарга тырыша. Мәсәлән, 1922 елның 30 октябрендә ул Петроград мөселман җәмәгатьчелеге (колониясе) ата-аналар комитеты исеменнән Петроград губернасы милли азчылыклар халык мәгарифе бүлегенә мөрәҗәгать итеп, Петроград Җәмигъ мәчете каршында мәктәп ачу теләген җиткерә. Гариза болай яңгырый: «*Арабская грамота, тюрко-татарский язык и его грамматика, история тюрко-татар – все эти предметы являются важным элементом общего образования детей мусульман, но эти предметы не включены в программу советских школ I и II ступеней.*

*Поэтому родительский комитет Петроградской мусульманской колонии открывает школы арабской грамоты, тюрко-татарского языка для мусульманских детей, девочек и мальчиков, занятия в которых будут начинаться после советских школ и будут продолжаться максимум 1 ½-2 часа.*

*Первая наша школа будет помещаться в здании соборного храма, вторая – по Гороховой улице, угол Фонтанки, дом 57.*

*Школы будут содержаться за наш счет.*

*Преподавателями второй нашей школы намечены бывшие преподаватели советских школ Мустафа Юнусов и Васфия Юнусова.*

*Обучение в наших школах будет бесплатным.*

---

[1] Тагирджанова А. Н. Күрс.хезм. Б. 165–166.

*Члены комитета: М. Бигеев, мулла, ул. Бронницкая, 17, кв. 21.*

*А. Тухфатуллин, организатор лесной артели, ул. Ямская, 4, кв. 5.»*

Шул ук елның 6 декабрендә Муса әфәнде гаризасын яңартып, кабат юллый[1], әмма, дингә, дин әһелләренә каршы дәүләт тарафыннан алып барылган сугышчан пропаганда баш күтәргән илдә бу эшнең барып чыкмавын фаразлау кыен түгел.

Әлбәттә, югарыда бәян ителгән хәлләр яңа властька карата ярату хисләрен үстермәгәннәр, шуңа күрә Муса әфәнде совет властена булган өмет вә хыяларыннан тиз арада тәмам ваз кичә һәм, гомумән, коммунизм тәгълиматыннан тәмам бизә. Аның кәефенең һәм эчке халәтенең үзгәрүе югарыда инде искә алынган «*Ислам милләтләренә дини, әдәби, сәйәси мәсьәләләр, тәдбирләр хакъкында»* (шулай ук «*Исламийәт әлифбасы»* дип тә аталган) исемле китабында бик яхшы сизелә. Бу китап турында сүзебез алга таба әле булыр.

### «Русия мөселманнарының мәдәни дәүләтләргә мөрәҗәгатьләре»

1922 елда мөселман җыеннарының берсендә Муса әфәнде халыкның ачлыктан интегүләрен күтәрә алмыйча, аларга ярдәм итү юлларын табарга теләп бер мөрәҗәгать яза һәм аның кабул ителүенә ирешә. Ул мөрәҗәгать болай яңгырый:

*Дәвамлы сугыш вә куәтле инкыйлаб фетнәләренең нәтиҗәләрендә, Русия җирләрен тәмам басып алган дәһшәтле ачлык, һәртөрле үтергеч хәстәлек, гаять нык корылык иң югары дәрәҗәләргә иреште. Һәр милләттән артык Русиянең ислам вилаятьләре ачлык, хәстәлек корбаны булды.*

*Киләчәкнең күренешләре тагын да яман. Иген кырларының күбесе буш калды. Киләчәк елларның ачлыклары тагын да көчлерәк, гомумирәк булачак. Бүгенге дәһшәт шулай дәвам итсә, ач вилаятьләрдә яшәгән мөселманнарның йөздән сиксәне ачлык, хәстәлек корбаны булачак.*

---

[1] Тагирджанова А. Н. Күрс.хезм. Б. 169.

*Иганә чараларының һәрберен һәрьяклап куллану өчен, иганә хезмәтләренә рухани идарәләрне дә дәгъвәт итеп; хөкүмәт бу якын заманнарда Нәзарәт исламия әгъзаларына да олы ихтыяр иреге бирде, чара күрү хосусларына рөхсәт бирде.*

*Русия мөселманнарының Диния нәзарәте, хөкүмәт идарәләренең зур ярдәмнәренә таянып, эш башлады: Москвада Иганә мәркәзе*[1] *корылды, илнең вилаятьләрендә бүлекчәләрен дә ачты. Мәдәният дөньясының киң күңеллелек капкаларына үзенең вәкилләрен дә якын көннәрдә күндерәчәк булды.*

*Русия ачларына ярдәм итүче Америка комитетына, Алманиядән җибәрелгән Кызыл хач җәмгыятенә, Женева конференциясе тарафыннан күндерелгән доктор Нансен*[2] *хәзрәтләренә Русия мөселманнарының Диния нәзарәте бөтен Русия мөселманнарының иң ихлас олы шөкерләрен белдерә.*

*Насаранияt*[3] *чиркәүләренә, бөтен насараларга, насараларның бөекләренә Коръән кәримнең һәр сүрәдә дә кямил ихтирамнарын нигез итеп: Сахиб-е Коръән Мөхәммәд, галәйһис-саләт вәс-сәлам, хәзрәтләренең ярдәм сорау рәвешендә дә, дуслык белдерү рәвешендә дә Хәбәш*[4] *һәм Рум*[5] *насараларына мөрәҗәгатьләрен дә, зур ярдәмнәрен дә бүген шөкер теле белән насаранияt бөекләренә белдереп; Русия мөселманнарының Диния нәзарәте ислам мәчетләре исеменнән насараларның бөекләренә ярдәм сорап мөрәҗәгать итә.*

*Сезнең киң күңеллелек капкаларына мөрәҗәгать итәчәк ышанычлы вәкилләребезне, Изге Инҗилнең олы фәрманы белән гамәл итеп, ихтирам белән каршы алыгыз!*

[1] Иганә мәркәзе – ярдәм күрсәтү үзәге.

[2] Нансен (Фритьоф Ведель-Ярлсберг Нансен; 1861–1930) – норвегияле котыпларны өйрәнүче галим, зоология докторы, физик океанография фәненә нигез салучы, сәясәт һәм җәмәгать эшлеклесе, хәйрияче, 1922 елгы Тынычлык өчен Нобель премиясе лауреаты. 20–21 нче елларда Идел буенда ачлыктан интегүчеләргә гуманитар ярдәм күрсәтү эшенә зур өлеш керткән оештыручы.

[3] Насаранияt – христианлык.

[4] Хәбәш – Эфиопия.

[5] Рум – Бизанс (Византия).

*Урта гасырларда ислам мәктәпләрендән, ислам көллиятләреннән насараларның зур файда күргән булуларын бүген хәтерләрегезгә алып, бөтен мәктәпләрегезнең ишекләрен ач фәкыйрь мөселманнарның ятим балаларына бүген киң итеп ачыгыз.*

*Дәһшәтле Җиһан сугышларыннан соң, бөек инкыйлаб туфаннарыннан соң, ачлык, юклык этәрүе белән, олы зарурәт юлы белән сезгә бүген мөрәҗәгать иттек. Хөрмәт күрсәтеп кабул итегез».*

Бу документның кабул ителеп адресатка ирештерелгән вакытта кайда басылган булуы, кемнәрнең кулына барып җитүе әлегә мәгълүм түгел. Аны без Муса әфәнде тарафыннан 1933 елда басылган китапларның берсендә таптык һәм, 1922 елга караган булуы сәбәпле, хронологик тәртипне саклап, бу урында китердек. Әмма 1933 елда Муса әфәнде бу мөрәҗәгатьне бастырганда аның турында бер белешмә кебек мәгълүмат бирә. Әлеге өстәмәнең, зур тарихи әһәмияткә ия булып, шул вакыттагы вазгыятькә кагылышлы кайбер фактларны яктыртуы сәбәпле, аны да биредә, 1922 ел хәлләренә караган өлештә китерергә булдык: «*Мөрәҗәгать карары 1922 елның ахырларында кабул ителгән иде. Бу мөрәҗәгатьнең сурәте минем каләм белән язылган иде. Азмы-күпме карашлар төрлелеге булса да, ниһаятьтә, мөрәҗәгать карары кабул кылынды.*

*Мәдәни дәүләтләргә мөрәҗәгать итә алмасалар да, Төркия төрекләренә ике вәкил күндерелде.*

*Төркия төрекләренә мөрәҗәгать мәсьәләсендә мин каршы идем. Ныклап каршылык күрсәткән идем, чөнки ояла идем. Сугыш елларында дошман тарафында зур көч булып, Төркия өстенә йөз меңләрчә гаскәребезне юллаган идек, җирләрен, авыл-карьяләрен харап иткән идек. Төркия мөстәкыйльлеге өчен сугышканда читтән күзәтеп торучы идек. Төркия төрекләренә ярдәм кулын сузу ул чакта безгә фарыз иде. «Мөрәҗәгать итсәк, соң локмәләрен дә Төркия төрекләре безгә, әлбәттә, бирер! Ләкин бераз оялырга ляземдер!» – дигән идем.*

*Вәкилләребез, ни өчендер, буш кул белән кайтып төшсәләр дә, төрек халкы Русия ачларына унбиш-йегерме кадәр зур вагоннарда төрек офицерлары карамагында азык-төлек юллады. Мөхтәрәм исеме хатеремдә калмады, баш офицер безнең гаять салкын вилаятьләребездә авыл бичараларына азык-төлек өләшкәндә, өстендә кышлык киеме булмау сәбәбе белән бәлки, авырып китеп, шул юлларда шәһит булды. Ягъни, мәрхәмәтле вә хөрмәтле олы кунакларына бер бүрек, бер толып бирү дә ул чакта бөтен Русия мөселманнарының кулыннан килми иде. 1923 нче елда гомуми корылтаебызда ул олы кимчелегебез аркасында хәсрәтле ачынуыбызны белдердек, бәян иттек, мөхтәрәм шәһитнең рухларына «Фатиха» укыдык, дога кылдык. Башка бер чарабыз юк иде. Мөрәҗәгать бер мәҗбүрият иде. Шушы гүзәл форсаттан файдаланып, мәдәният дөньясына вәкилләребезне ул вакыт күндергән булса идек, йөзләрчә ятим балаларыбызны мәдәният мәктәпләренә, көллиятләренә, ихтимал, кабул иткән булырлар иде; Русия мөселманнарының сәяси хәлләре хакында гүзәл пропаганда файдалары да, мөгаен, хасил булыр иде.*

*Нух туфаннарында Нухның авылларын сулар батырган булса, бөек инкыйлаб, дәһшәтле ачлык, көчле хәстәлек туфаннарында безнең шәһәрләребезне, авылларыбызны кан туфаннары, күз яше ташкыннары батырган иде. Кулларыбызны юмартлык ишекләренә сузу хурлыкларына ул вакытта без мәҗбүр булганбыз икән, ул чактагы хәлебезнең авырлыгы бөтен хәрамнәрне мөбахка әйләндерәчәк кадәр дәһшәтле иде. Аллаһ белә – безнең акланырлык сәбәпләребез бар иде! Балаларыбызны мәдәният дөньясының мәктәпләренә озату эшләре, Аллаһ белә – иң зур максатыбыз иде. Без берара йөзилле-икейөз кадәр ятимнәребезне үз исәбебезгә күндерә алсак та, ниһаять, яһүд балаларыбызның фетнәсе аркасында нәфәкалары*[1] *киселеп, балаларыбыз тар-мар булды. Соңыннан бу эш тулысынча тыелды.*

---

[1] нәфәка (гарәп) – ятимнәргә, хатыннарга тотыла торган акча һәм матди чыгымнар.

*Әхлакый, дини тәрбиядән, мәктәп тәрбиясеннән, гаилә эчендә милли тәрбиядән тәмам мәхрүм калган ислам балалары коммунистларның «семилетка» мәктәпләрендә коммунизм пионерлары булып җитешәчәк, мондан соң пятилетка эшчеләре булып көн күрәчәктер.*

*Утыз миллион төрек*[1] *вә Өммәт мөхәммәдия*[2] *балаларының киләчәкләре будыр!*

*Коммунизм тәҗрибәләренең мондый гыйбрәтләрен мәмләкәтебездә*[3] *күрдек. Инде моннан да яман нәүбәт Төркестан белән Чин капкаларына барып иреште.*

*Ай, бу соңгы ике юлны укыган иманлы төрек,*

(واذ ستنصروكم فى الدين فعليكم النصر!)[4]

*Нүн хәрефе урынына, мескенлек дәһшәтенең тәэсире белән, зәл хәрефе яздым*[5]. *Җөмлә дә шарт җөмлә түгел, хәл җөмләгә әйләнде. Киләчәкне түгел, үткәнне белдерә торган булды!»*[6]

1921 елда Төркиядә чыгып килгән «Мәхфил» исемле гыйльми, әдәби, иҗтимагый журналда Муса әфәндегә багышланган «Мөҗтәһидләрнең мөҗтәһиде» атлы бер язма чыга[7]. Таһир әл-Мәүләви имзасы белән чыккан бу махсус редакцион язмада исеме телгә алынган мәкаләнең журналда басылмавының сәбәпләре аңлатыла. Авторның Муса Бигиевкә карата *мөҗтә-*

---

[1] төрек – биредә Русия мөселманнары – татарлар һәм башкортлар күздә тотыла.

[2] Өммәт мөхәммәдия – Мөхәммәт пәйгамбәрнең өммәте, ягъни мөселманнар.

[3] мәмләкәт – ил.

[4] Коръән кәримнең 8 нче «әл-Әнфаль» сүрәсендәге 72 нче айәте: (وَإِنِ اسْتَنصَرُوكُمْ فِي الدِّينِ فَعَلَيْكُمُ النَّصْرُ), ягъни: «әгәр алар диндә сездән ярдәм сорасалар, аларга ярдәм итәргә тиешсез».

[5] Айәтнең беренче сүзендәге үзгәреш күздә тотыла, ягъни автор (وَإِنِ) кисәкчәсе урынына (واذ) кисәкчәсен язган булуына игътибар иттерә.

[6] Чыганак: «Тарихның онытылмыш сәхифәләре». Берлин, 1933. 18 б.

[7] Мөҗтәһидләрнең мөҗтәһиде // Мәхфил. 1 том, 14 сан. Август-сентябрь, 1921. Б. 22–23.

*һидләрнең мөҗтәһиде*, *остаз мөхтәрәм*, *голәмаи мөҗтәһидәи хакыйкыя*, *бер надидә голәма*, *Әбу әл-Мөҗтәһид*, *даһи* кебек шәрәфле билгеләмәләр куллануы редакция тарафыннан кабул ителә алмый, имеш. Әмма Бигиевкә багышланган мәкаләнең басылып чыкмавы, мөгаен башка сәбәпкә бәйле булса кирәк. Чөнки автор Госманлы дәүләтенең әүвәлге шәйхелисламы Мостафа Сабри хәзрәтләренең Муса Җаруллаһка каршы чыгуын игътибар үзәгенә алып, аны тәнкыйтьләүдә гыйлем иясенә килешми торган алымнар куллануына ризасызлыгын белдерә: «*Мостафа Сабри әфәнде тәфрикасендә Муса Җаруллаһ хәзрәтләренең хакыйкый мөтдәйййн улдыгыны унутуб вә йә билмәйүб «мөҗтәһидләрнең пишва-и диниясе» дия тәгарруздан бер түрлү кәндесене аламийур. Занн идәрез ки халыкның голәмадән таныдыгы Мостафа Сабри әфәнденең утуз биш миллион кадәр бер нөфүсә малик улан Русия мөселман кардәшләремезнең һәм галәме исламиятнең голәма мөҗтәһидә -и хакыйкыйәсе улан Муса әфәнде хәзрәтләренә тәгарруз каләмиядә булунмасы аслән тугры улмаса кирәк. Муса әфәнде Бикиеф хәзрәтләре фикерләрейлә, гыйлемейлә, каләмейлә заманның голәмасе, хәтта мөселманлыгның мәдаре ифтихары вә галәме исламиятнең баш таҗыдыр»*,– диелә мәкаләдә. Ягъни, күргәнебезчә, Муса әфәнденең әсәрләре Төркиядә укылып-танылып кына калмаган, аның ул әсәрләрендә бәян иткән идеяләре госманлы җәмәгатьчелегендә кызу бәхәсләр кузгатканнар, милли матбугат сәхифәләренә ташып чыгып, Төркиядәге рухи һәм интеллектуаль хәяткә җан вә хәрәкәт өстәп торганнар.

## Качып китмәвенең сәбәпләре

1923 елның башында Муса әфәнде үзенең күптәнге дусты Һелсинки имамы Вәли-Әхмәт Хәкимгә бер хат яза. Әлеге хатта әйтелгән сүзләрдән Муса әфәнденең илдән качып китмәвенең сәбәпләре аңлашыла:

«*Җәнүб һавасы кирәк икән, Төркия, Төркестан ишекләре ачык. Сәяси «дубина»ларның*[1] *эзләреннән сәфәр кыйлуның*

---

[1] Сәяси «дубина»лар – сәясәттә үзләрен күрсәтә алган олпат затлар күздә тотыла булса кирәк.

*кирәге юк. Төркиягә сәяхәт әһәмиятсез булмас, әлбәттә. Берлин, Лондон, Париж урамнарында сәргярданлык*[1] *башка; җәнүб һаваларында хасталык заруряте белән йөреп Төркия хәлләреннән, ислам дөньясының хәлләреннән хәбәрдарлык кәсеп итү – башкадыр. Ягъни сәяхәтегез белән Садри сәргярданлыгы арасында аерма, әлбәттә, зурдыр. Садри әфәнделәр таләп юлында, тәҗрибә һәм гыйлем эстәү юлында йөрсәләр – яхшы; ләкин хәрәкәтләренә сәяси төс, сәяси максат бирсәләр – хатадыр. Русия хәрәкәтләреннән Русия мөселманнары да, Һиндестан мөселманнары да файдалана. Бәрәкәтулла кебек мәүләвиләрнең Москвага килүләре, анда торулары Садри кебек «мөхтәрият» башлыкларының Лондонда, Парижда сәргярданлыкларыннан, әлбәттә, бәрәкәтлерәктер. Рус кебек бай һәм ифрат садә*[2] *бер милләт белән гүзәл мөгамәләдә булудан бүген гаҗиз калган булсак, Рус кебек зур бер милләтне истихдам иткән*[3] *яһүдиләргә әйтер сүзегез калмаячак»*.

### «Ислам милләтләренә» исемле китабы һәм икенче тоткарлану

1923 елның июнь аенда Уфада Башкорт Автономияле җөмһүрияте мөселманнарының корылтае үткәрелә. Муса әфәнде аның эшендә дә катнаша. 8 октябрьдә Казан имамы Әмирхановка хат язып, муллаларны Төркия Бөек Милләт Мәҗлесе үтенечен үтәү йөзеннән, Грузия белән Балкан якларыннан куылып, Төркия күченүче мөһаҗирләргә матди ярдәм җыю эшен Татарстанда да оештырырга тәкъдим итә.

Шул ук елның көзендә Берлинда Гаяз Исхакый редакциясендә Муса Бигиевнең ислам конституциясе буларак танылган «***Ислам милләтләренә дини, әдәби, сәйәси мәсьәләләр, тәдбирләр хакъкында***»[4] («***Исламийәт әлифбасы***») («Ис-

---

[1] Сәргярданлык – тирә-якны гизеп йөрү; әйләнеп керү; күңел ачу.

[2] Садә – гади, беркатлы.

[3] истихдам иткән – хезмәт иттергән.

[4] Муса Җаруллаһ. Ислам милләтләренә дини, әдәби, иҗтимагый, сәйәси мәсьәләләр, тәдбирләр хакъкында. Берлин, 1923. 110 б.

лам милләтләренә дини, әхлакый, сәяси мәсьәләләр, чаралар хакында») исемле «шанлы төрек гаскәре шәрәфенә тәэлиф кылынган» (ягъни данлыклы төрек гаскәре хөрмәтенә язылган) әсәре басылып чыга. Төрек гаскәре дә тиктомалдан искә алынмаган. Беренчедән, аның Беренче Җиһан сугышында күрсәткән каһарманлыгы, аеруча Чанак-кальга сугышындагы Антанта армияләрен һәм бәхрияләрен (флотларын) Кара диңгезгә үткәрмәве Муса әфәндене нык сокландыра. Чыннан да, Беренче Җиһан сугышында Госманлы Дәүләт-е Галиясенең гарәпләр яшәгән биләмәләрендә шул ук гарәпләр Бөекбритания тарафына күчеп, төрекләргә каршы сугыш башлап, хиләфәтне тоткан һәм хәлифәтнең тәхетен саклаган илнең аркасына хәнҗәр кадаган мәлдә төрек мөселманнары җаннарын фида кылып дөньяның иң алдынгы илләреннән җыелган дошман көченә каршы торалар. Шуңа күрә, китап сатышыннан керәчәк бөтен керемне Муса әфәнде «*Җиһан мөхарәбәсендә шәһид улмыш төрек гаскәрләренең ятимләренә»* багышлый.

Бу китапның матди чыгымнарын үз өсләренә Финляндиядә яшәгән милләттәшләребез бертуган Җәмалетдин угыллары һәм Зиннәтулла[1] Әхсән Бүре алалар. Китапның гомуми тиражы 5000 данә тәшкил итеп, шуның 1500–2000 данәсен Муса әфәнде Совелар Берлеге мөселманнары арасында таратырга, ә калган өлешен, Берлиннан Төркиягә озатып, шунда сатуга чыгарырга ниятләгән. Китапны Төркиядә сату өчен рөхсәтне Муса әфәнде Төркиянең Мәскәүдәге илчелегендә алган була.

Китапның кереш сүзендә Муса әфәнде марксистик тәгълиматны коры тәнкыйтькә генә дучар иткән дип әйтү дөрес

[1] Зиннәтулла Әхсән Бүре (Зиннәтулла Гыймадетдинов; 1886–1945) – Финляндия татар диаспорасының күренекле вәкиле, сәүдәгәр; чыгышы белән Түбән Новгород губернасы Актук татар авылыннан. 1916 елда имтихан тапшырып имамлык итә, җирле татарларның дини-рухи тормышларында күренекле раһбәр булуга ирешә, фин халкын ислам дине белән таныштыра, тарихта беренче мәртәбә Коръәнне фин теленә тәрҗемә итә. Ул ясаган Коръән тәрҗемәсе 1942 елда Тампере шәһәрендә басылып чыга. Һелсинки татар зиратында күмелгән.

түгел, чөнки галим аның уңай, дөрес якларын да күрсәтә. Әмма асылда Карл Марксның даһи һәм шул ук вакытта төшенкелекле рухлы акылының җимеше булган бу тәгълиматның нигезе үк черек булуын фаш итә. Тәнкыйтьтән тыш, Муса әфәнде бу китабында ул чорда вакыйг булган бөтендөнья геополитик вазгыятькә дә тирән анализ ясый. Китапның бу үзенчәлеге Муса әфәнденең ислам дөньясында аның замандашлары булган фикер ияләренең абсолют күпчелегеннән ике-өч баш югары булуын күрсәтә, чөнки дөнья сәясәте, иҗтимагыять, икътисад, мәдәният, әдәп-әхлак яссылыкларында аңа хас булган фикер йөртү киңлегенә һәм вазгыятьне тиешле кадәр тирән аңлау куәтенә ия булган башка берәүне табуы, миңа калса, мөмкин түгел. Моннан тыш Муса әфәнде бу әсәрендә ул заман мөселман тормышының һәм, гомумән, ислам дөньясының кискен проблемаларын, өммәтне борчыган кыенлыкларны, аларның сәбәпләрен бәян итә; ислам дөньясының гасырлар буе кичергән фаҗига һәм бәлаләрдән коткару чараларын, аны артка тартып, тәрәкъкый итәргә мөмкинлек бирмәгән рухи кризистан чыгу юлларын күрсәтә; дини, рухи, мәдәни, икътисади тәрәккыять үрләрен яуларга чакыра. Бу китабында да, аннан алдагы әсәрләрендә дә Муса әфәнде, гадәттәгечә, шәригатьтә каралган дини йолаларны үтәү белән генә чикләнмичә, кешеләрдә фикер вә ихтыяр ирегенуятырга өнди һәм шул нигездә иҗтиһад һәм ирекле иҗат юлына чыгарга дәгъвәт итә. Шулай итеп, галим ислам динен җанландырып җибәреп, аны югарырак баскычларга күтәрергә, мөселманнарны алдынгы, фән вә техник прогресстан файдаланучы җәмгыятькә әверелдерергә чакырган. Аның фикеренчә, шундый ирекле акыл ияләре генә мөселман җәмгыятен алга таба, бөтен кешелек дөньясы атлаган юнәлештә үстерә алачаклар. Шушы чаралар ярдәмендә Муса Бигиев ислам диненең дөньякүләм абруен һәм әһәмиятен арттырырга, аны бөтен кешелек дөньясын үзенә җәлеп итә алырлык алдынгы, матур, әхлакый бер яшәү рәвешенә әверелдерергә теләгән.

«*Ислам милләтләренә»* исемле китабында Муса әфәнде болай дип яза: «*Кешелек дөньясының бүгенге халәтен тән-*

*кыйть иткәндә Карл Маркс, әлбәттә, хаклы. Әмма киләчәкне юраганда ул һәр ноктада ялгышкан. Цивилизацияне күмәк фәкыйрьлеккә нигезләп кору мөмкин түгел. Җәмгыятьне тәшкил иткән кешеләрнең хокукларын һәм иреген аяк астына салып таптап, киләчәкне төзеп булмый. Мондый фикерләр сабыйларча зәгыйфь акылга гына хас була ала. Халыкның фикерләвен, калебләрен, иманнарын һәм әхлагын үзгәртмичә башланган революция тетрәнешләре фәкыйрьләргә һәм эшчеләргә файда һәм игелек китермәячәк*».

Китапның соңгы сәхифәләрендә Гаяз Исхакыйның «*Кариъин кирамның дикъкатенә»* («Хөрмәтле укучылар игътибарына») исемле бер аңлатмасы урнаштырылган. Анда ул болай дип язган:

«*Шу китабның тәсхыйхы йапдыгым вакыт нә китабның тәгъкыйб итдеке фикра, нә дә тарз-ы ифадә вә өслүбенә катгыйан карышмадым. Фәкать бәгъзы бер шөбһәйи мөҗиб сайдыгым йиирләрдә тәхте әс-сәтыр күчек ийзахатдә булундым. Шуны да галәвә итмәле ки, мөхәррирнең китабында күстәрелән тәдбирләр, узын узадийә сайдыгы маддәләр, кагыйдәләр нә Милләт Мәҗлесе тарафындан кабул иделмеш әсасләрдер; нә дә гыйльми бер мөъәссәсә тарафындан ихзар иделмеш каванинләрдер; бунлар фәкать Муса әфәнденең кәндүсенең иҗтиһад шәхсийәсенең сәмәрәләредер. Шуның ичүн, табигый, шималь төрекләре гомумән вә анларның милли мөъәссәсәләре хосусан, бу китабның мөндәриҗәты хакында катгыйан мәсъүл дәгелдер. Китабның мәъаль вә фикерендәге, тарз-ы өслүб, вә ифадәсендәки бөтен мәсъүлийать тәмамыйлә мөхәррире Муса әфәнденең фәкать кәндүсенә гаъиддер.*

*Китабның мосаххыйы Гаяз Исхакый»*.

Әлеге хезмәт Муса әфәнденең язмышына бик нык тәэсир итә: коммунистик идеалларны тар-мар итүе аркасында һәм Русиядән совет властеның дошманы буларак һиҗрәт кылган Гаяз Исхакыйның ул китапны редакцияләве сәбәпле китап басмаханәдән чыгар-чыкмас Муса әфәнде 1923 елның кара

көзендә, 17 ноябрьдә Петроградтагы «Мәскәү вокзалы»нда ОГПУ тарафыннан кулга алына һәм Мәскәүгә озатылып, ОГПУның эчке төрмәсенә кертеп бикләнелә.

НКВДда Муса Бигиевкә карата ачылган Делодан бер өземтә: «*Дело возникло согласно ряда получаемых в ВООГПУ материалов, указывающих на Бигиева, как на одного из виднейших идеологов панисламизма /Иттихадистов/... Последние материалы говорили, с одной стороны, о стремлении М. Бигиева выехать в Калькутту /Индия/ для участия на всемусульманском с'езде и, с другой – на издание им в Берлине книги, в которой БИГИЕВ явно старается показать всему мусульманскому миру неприемлемость для мусульман Соввласти... Начиная с введения и кончая послесловием, книга проникнута нескрываемой ненавистью к принципам Советского строительства*»[1].

Муса әфәнденең кулга алынуының төп сәбәбе «*Исламийәт әлифбасы»*ның басылып чыгуы булганга күрә, беренче нәүбәттә аннан бу китабы турында мәгълүмат таләп ителә. Бу турыда Муса әфәнде түбәндәге аңлатмалар биргән:

### *По поводу его книги «Ислам миллетлерина»*[2]

26–27 ноября1923 года

*У меня есть одно важное: то, что у меня нет тайного, скрытого. В течение мировой войны и настоящей революции под сильным давлением разных обстоятельств много думал, имел, как и все имеют, свои взгляды на разные вопросы по разным, более менее, важным событиям. Свои соображения, свои взгляды написал в своем обращении к Великому Собранию и в предисловии к моей книге, и больше нигде не распространял. Это было давно, два-три года тому назад. Книга моя лежала долго, где-то валялась, а когда стали печатать, я не имел возможности получить корректуру и, таким образом, не мог исправить свои старыя ошибки. Но ныне я готов чисто по своей воле исправить мои ошибки, хотя бы в прило-*

[1] [АСД. Л. 70–74]

[2] Документның Делодагы исеме.

*жении к моей книге, где я желаю показать и типографские опечатки и ошибки самого автора. Я это сделаю и добровольно. Если мне будет дана возможность, то я это сделаю.*

*Но все таки я сказал бы, что образованный мир тюрков, который хорошо понимает меня, мои книги, после чтения моей последней книги получил бы хорошие впечатления по отношению к Соввласти, так как все события революционного времени я показал как неизбежные необходимые следствия грехов старого строя, прежней власти, старой религии и как вполне справедливые божественные наказания. А это очень понятно в глазах каждого верующего: Божественная кара, нисходящая на грешную землю через Архангела Гавриила, по верованиям мусульман, не есть вина Гавриила, не есть жестокость Гавриила.*

*Ведь это я прочитал стих известного арабского поэта:* […]* *когда говорил о Великих Вождях мировой революции: «Люди, когда совершают богослужение (добродетель), подобны ангелам, а когда творят революцию, то они гениальные исполины (Геркулесы)». Такое слово только мог сказать на съезде мулл. И это было очень искренне.*

*Я, как мне кажется, могу считать мои ошибки в моей книге только фантастическими, только поэтическими, происшедшими только от вольной моей фантазии, воспламенившей перед страхом разных слухов и событий, которым я мог дать ход, когда писал. Мне и кажется, что они могут не считаться политическими…*

*Мой язык в последней моей книге, особенно в предисловии к ней, не очень прост, а ученый литературный. Не каждый читающий может познать все мои мысли и не каждый переводчик может передать в буквальном переводе так правильно, так точно, как я излагаю. Моя книга в основной ее части содержит очень много трудных, сложных, пока еще никем не разрешенных спорных ученых вопросов.*

*Поэтому желал бы иметь среди экспертов и таких солидных ученых, как профессор-тюрколог гражданин Гордилевский, и как Абдулла эфенди Гисматуллин.*

*26 ноября 1923 го года Муса Бигеев.*

*27 нояб[ря].*

*Верно, я написал мою книгу давно; после два три года она была издана; но я не распространил ее и обратился в Главлит получить разрешение. Не дадут разрешение, она так и останется или будет исправлена с приложением или как-нибудь иначе.*

*Сделаю все, что смогу. Муса Бигеев»*[1].

Тикшерү барган көннәрдә Муса әфәнденең «***Төркия Бөек Милләт Мәҗлесенә мөрәҗәгате***»нә дә игътибар ителә: «*...Бигиев поручил Субхи передать В.Н.С.Т. обращение, в коем... особенно внимательно разбирал вопросы об отношении мусульман к Соввласти. Здесь Бигиев еще резче, чем в своей книге, нападает на Соввласть, переходя зачастую от нападок к прямым указаниям на то, что РСФСР более опасный враг для мусульманского мира, чем Англия.*

*Это обращение, по словам Бигиева, он хотел направить в ВНСТ в качестве раз'яснения к своей книге «Мусульманским нациям»»*[2]

Бу адымын аңлатып Муса әфәнде түбәндәге аңлатмалар биргән: «*Такими удачными случаями я познакомился с положением Турции и решил использовать Исмаил-Субхи в моем обращении.*

*Турки очень честные и очень убежденные мусульмане. Только поэтому я дал себе, как носителю Корана, право давать какие-нибудь советы по разным вопросам жизни и даже политики, так как Коран очень ясно и очень правильно дает свое учение и строгое повеление по каждому вопросу жизни и политики.*

*Великий ученый индус мусульманин Мевлеви-Убейдулла Сахиб, который несколько месяцев тому назад уехал из России в Турцию, в нашей беседе раз сказал мне очень правильно:*

[1] Допрос протоколы. АСД. Л.25–26.

[2] Допрос протоколы. АСД. Л.70–74. Заключение.

*«Кто из мусульман не знает вторую главу Корана, тот не может знать правильную политику».*

*Я и сам был тоже такого же убеждения. А потому дал себе право излагать им свои советы, даже в политических вопросах. Много написал об экономической политике, о национальной политике, много написал о внешней политике, и стал разумным сторонником согласия Турции с Россией, говорил о колоссальных интересах России в согласии, более чем Турции.*

*И мне казалась очень странной политика недоверия Советской власти к представителям Турции и представителям мусульманского востока, а коммунистическая политика на Востоке по отношению к религии Ислама и к Корану казалась просто вредной для самой Советской власти, большой ошибкой, создавшей басмачество в Туркестане. Я был убежден в этом, поэтому имел право и бодрости говорить-читать лекции в защиту религии, громко, гласно, но не тайно говорил, что основной закон Советской власти дал свободу, дал право каждой религии, не преследует никакую религию, хотя коммунисты, читавшие только «Азбуку Коммунизма», могут иметь вражду и могут гонять религию, но ясно, что поведение коммунистов не закон Советской власти. Лекции такого содержания я много читал и много говорил.*

*Но слабый мой голос не был услышан никем, а стал главным поводом моего ареста.*

*В конце моего обращения я предложил свои труды Великому Собранию и просил издать их в честь Турецкой Армии.*

*Мое обращение начато было в конце 20-го года и было послано в конце 21-го года. Обстоятельства изменились. И я бы ныне написал бы, хотя немного иначе»*[1].

Муса әфәнденең гаепле булуын дәлилләү йөзеннән следствие аның чит ил вәкилләре белән аралашуына һәм моның законсызлыгына басым ясый. Бу мәсьәләгә багышланган сорау алу протоколы да сакланган. Әлеге документта, беренчедән,

---

[1] Допрос протоколы. АСД. Л.25–26.

Муса әфәнденең үзен тотышы игътибарга лаек; икенчедән, сорау алу дәвамында аның нинди холык иясе булуы чагыла:

### *«Протокол допроса гр. Муса Бигеева*

*от 16 ноября с/г.*

*В[опрос]. От чьего имени Вы обращались к ВНСТ?*[1]

*О[твет]. От имени всех мусульман-тюрков. Ибо я, как носитель Корана, считаю себя вправе.*

*В. Считаете ли Вы, что каждый из 15000 мулл, проживающих в СССР, имеет право обращаться от имени всех мусульман-тюрков?*

*О. Имеют право, ибо их также уполномочивает Коран.*

*В. Думаете ли Вы, что все 15000 мулл думают о Соввласти так же, как Вы?*

*О. Считаю, что я думаю правильно, но как думают все другие, я не знаю.*

*В. Считаете ли Вы, что последний съезд духов[енства] в Уфе был также выразителем вашего мнения?*

*О. Да, безусловно.*

*В. Чем же объяснить, что в Вашем обращении в ВНСТ., вы утверждаете, что Советская власть больший враг народов Востока, чем Англия?*

*О. Я не говорил, что Советская власть, а говорил, что коммунизм.*

*В. Чем объяснить, что Уф[имский] съезд мусдухов[енства] осуждал туркест[анских] басмачей, называя их бандитами, а вы называете их воинами Турции?*

*О. Я не был согласен с некоторыми словами резолюции съезда, а именно с названием басмачей бандитами.*

*В. Чем объясняется Ваше утверждение ВНСТ, что в Сов-Россия, подобно Англии, ведет завоевательную колониальную политику?*

*О. Непризнанием религиозных прав мусульман и гонениями Ислама.*

---

[1] ВНСТ – Высшее национальное собрание Турции (Төркия Бөек Милләт Мәҗлесе, ТБММ).

*В. В чем выразилось, по-Вашему, гонение против Ислама в СовРоссии?*

*О. Мы лишились своих религиозных прав, которые нам дает Коран. Непризнанность нашего брака, наследства, права собственности и другое. Применяются недопущенные нашими законами правила и меры.*

*В. Через кого Вы передали свое обращение ВНСТ?*

*О. Через Исмаила Субхи, члена ВНСТ и специальной комиссии.*

*В. Считали ли Вы себя вправе сноситься непосредственно помимо НКИД*[1] *с представителем иностранной державы?*

*О. По нашему мусульманскому закону, по повелению Корана, я должен был это делать.*

*В. Считаете ли Вы себя вправе по подобным вопросам обращаться к послу Турции?*

*О. Считаю, что вправе к нему обращаться.*

*В. По каким вопросам Вы считаете себя вправе обращаться к представителям иностранной державы?*

*О. По всем вопросам затронутым мною в своем обращении во ВНСТ.*

*В. Через кого Вы собирали материалы по всем затронутым в вашем обращении вопросам?*

*О. Собирал эти материалы сам.*

*В. Кто передавал вам сведения из Туркестана?*

*О. Недавно на выставке я встретился с Махмудовым, но сведения от него не получал, а с Мунавар Кари Абдурашитовым я в Москве не встречался никогда.*

*В. Кого вы встречали в Москве из Татарии?*

*О. С Мустафиным во время выставки.*

*В. Понимаете ли вы, что ваше поведение явно противоречит законам СССР?*

*О. Я считаю, что не противоречит законам СССР, а обращение ВНСТ может быть, противоречит этим законам.*

*В. Считаете ли вы себя гражданином СССР?*

---

[1] НКИД – Народый комиссариат иностранных дел (Тышкы эшләр комиссариаты).

*О. Да, считаю.*

*В. В таком случае обязаны ли вы подчиняться всем законам СССР?*

*О. Считаю, что не только я, но и все мусульмане СССР обязаны подчиняться всем законам СССР.*

*М. Бигеев.*

*Опрос производил П. Алексеев».*

Муса әфәнденең кулга алынуы турындагы хәбәр бөтен ислам дөньясына тарала һәм Финляндия татарларын аякка бастыра. Олуг галимне яклап чыгуда Финляндия татарлары, аерым алганда имам Вәли-Әхмәт Хәким, иң зур һиммәт, иң көчле активлык күрсәтәләр. Алар Милләтләр Лигасында Төркия вәкиле булып торган Төркия тышкы эшләр министрының урынбасары Исмәт-пашага мөрәҗәгать итеп, аңа француз телендә язылган хат юллыйлар, Төркиядәге матбугат чараларына телеграмма җибәрәләр. Телеграммада болай диелә: «*Бөтен ислам вә төрек дөньясында танылган вә хөрмәт ителгән голәмәдән Муса Җаруллаһ Биги әфәнде Русиядә кулга алынган. Үзен төрмәдән коткару хакына Совет хөкүмәте катында демаршлар үткәрүегезне үтенәбез*».

Төркиядә әлеге телеграмма Истанбулда чыга торган «Вакыт» һәм «Җөмһүрият», Әнкарада чыга торган «Хакимияте миллия» һәм «Йени гюн» кебек гәзитләрдә басылып чыга[1]. Моннан тыш «Сәбилерришад» журналының 20 декабрьдә чыккан санында «*Муса Җаруллаһ әфәнденең тәүкыйфе»*[2] («Муса Җаруллаһ әфәнденең тоткарлануы») исемле мәкалә басыла: «*Һелсинкфурс имамы Хәким әфәнде тарафыннан чикелән бер шайаны тәәссеф телеграфа күрә, Русия мөселманлары арасында бөек бер шөһрәт сахибы улан вә исламият хакында шайаны дикъкать нәшерийатыйлә тәгареф идән, ләһендә, галәйһендә берчук сүзләр сөйләнән, йазылар йазылан мәшһүр Муса Җаруллаһ әфәнденең большевик (Чә-*

[1] Mehmet Gormez, s.37.

[2] Муса Җаруллаһ әфәнденең тәүкыйфе // Сәбилерришад. 20 декабрь1923. 23 т., 580 сан. Б. 128.

*Ка) мәхкәмәсе тарафындан тәүкыйф улындыгы аңлашылыйур; Муса Җаруллаһ әфәнденең иң соң вазифасы Петроград имамәте иде. Кәндесейлә бәрабәр берчук мөселманлар да тәүкыйф улунмыш. Тәүкыйфнең сәбәбе «Дини, иҗтимагый, сәяси мәсьәләләр вә тәдбирләр хакында ислам милләтләренә» хитабән йазылан вә ахиран Берлинда табыг идилән бер китабдыр. Бу китабның бер нөсхәсе дә соң пуста илә идарәханәмезә күндерелмешдер. Кәч килдеге өчен тәдкыйка вакыт калмады.*

*Шанлы төрек гаскәренең шәрәфенә тәэлиф кыйлынан бу китабда шайаны дикъкать мөталәгать вә мөляхәзат улдыгы аңлашылыйур. Иншәэ Аллаһ киләҗәк һәфтә бу хосусда дәһа зийадә ийзахат виререз. Большевикларның шимдийә кадәр тәүкыйф итдекләре, үлдерлекләре голәманең хәд вә хисабы йукдыр. Фәкать Муса Җаруллаһ әфәнде унларла кабиле кыйас дәкелдер. Мәшар иләйһинең тәүкыйфе бөтен Русия мөселманларыны шиддәтле сурәтдә галякадар итмешдер.*

*Муса Җаруллаһ әфәнденең тәүкыйфендән бәхәс идән (Йңа Кафкасийа) дийур ки:*

*«Шөбһә йукдыр ки ошбу әсәрене, һәрнасыл улса да, табыг вә нәшер итдерән Муса әфәнде йакайи (ЧәКа) эленә вирәҗәкене билийурды. Буйлә икән тәрәддүд итмәдән нәшер әйләдеки әсәре илә кәндесене әфкяренә фида идәҗәк бер ришадат мәдәния күстәрмешдер.*

*Бу ришадатның җәзасы уларак Муса әфәнде, шимди Петроград (ЧәКа) сының будрумында утурыйур. Тәхәммел идәмәдеке әсарат һавасы эчендә мозтараб булунан мәгънәвияте, бу сурәтлә, бер нәуг итъминан булса билә, нәхиф булунан вөҗүде икенҗе дәфга уларак уградыгы бу әшкинҗәйә тәхәммел идәҗәкме?.*

*Күңел арзу идәрде ки матбугатның бу хосусда ибраз әйләдеки галякадарлык дәһа моттарид бер шәкел иктисаб әйләсен дә, Москва җәлладларына әхсас итдерсен ки рус коммунисларындан башка дүшүнән төрек вә ислам мөтәфәккирләрене кулай кулай тәнкил итмәк улмаз».*

Мәкаләнең авторы күрсәтелмәгән, әмма болай булу, гадәттә, язманың редакция тарафыннан язылганлыгын белдерә. Димәк, бу мәкаләнең «Сәбилерришад»та башъязар булган Мәхмәт Акиф әфәндене каләме белән язылган булуы ихтимал. Мәхмәт Акиф турында сүзебез алга таба булыр, ә хәзер «Сәбилерришад»ның чираттагы санында Муса әфәндене кулга алынуы сәбәбе булган китап турында чыккан мәкаләгә туктап алыйк. Әлеге мәкалә «*Коммунизм галәйһендә Муса Җаруллаһ әфәндене нәшер иттеки китаб»*[1] («Коммунизмга каршы Муса Җаруллаһ нәшер иткән китап») дип атала һәм искә алынган «Дини, иҗтимагый, сәяси мәсьәләләр вә тәдбирләр хакында ислам милләтләренә» китабының кыскартылып бирелгән кереш сүзеннән тора. Китапта «Китап бисмилласы» дип аталган кереш сүзнең күләме 25 сәхифә булса, журналда аның кыскартылган варианты 6 сәхифәгә кала. Әмма журнал кимәлендә бу да шактый зур өзек була. Нәтиҗәдә укучылар Муса әфәндене бу әсәрен кулларына алып укый алмасалар да, журнал публикациясе аша аның, һич югында, рухын тоеп, ялкынлы лөгате белән дә, азмы-күпме, танышу мөмкинлегенә ия булалар. «Китап бисмилласы» дип аталган бу кереш сүз безнең китаптагы кушымтада тулы вариантында татар теленә тәрҗемә ителеп бирелә[2].

Протестлар һәм ризасызлык белдерүләр, Ходайга шөкер, шактый тәэсирле булып, Муса әфәнде өчен җаннарын атып торган дусларын максатларына ирештерә. Кулга алынудан соң өч ай үтеп киткәч Төркиянең Стокһольм (Швеция) шәһәрендәге илчелеге Һелсинкидагы имамга һәм ул имамлык иткән татар-мөселман җәмәгатьчелегенә Муса әфәндене азат ителүе турында шатлыклы хәбәр җиткерә[3].

Бу вакыйгалар тикшерүгә һәм аның өстендә торучы түрәләргә тәэсир итсә дә, Делода, әлбәттә, чагылыш тапма-

---

[1] Коммунизм галәйһендә Муса Җаруллаһ әфәндене нәшер иттеки китаб // Сәбилерришад. 27 декабрь 1923. 23 т., 581 сан. Б. 132–137.

[2] Карагыз: III Бүлек. 16: Китап бисмилласы.

[3] Таймас Г. Б. Күрс.хезмәт. 20 б.

ган. Муса әфәнденең азат ителүе турындагы документларда болай диелә: *«Принимая во внимание частичное раскаяние БИГИЕВА и заверения его в из'ятии своей книги «Мусульманским нациям» с рынка, а также нежелательность применения к Бигиеву репрессивных мер в силу его популярности среди муснаселения, ПОЛАГАЮ:*

*1) Бигиева Муса Джарулла из-под стражи освободить, лишив его права проживания в Петрограде и его окрестностях, выселив его в г. Москву.*

*2) Дело прекратить и сдать в архив.*

*СПРАВКА: Арестованный Бигеев Муса Джарулла содержится во внутренней тюрьме ОГПУ.*

*Нач. II-го отделения ВООГПУ /подпись/ Петерс Утверждаю: Нач. ВООГПУ. /подпись/ Дьяков*

*24 января 1924 г.»*[1].

Шулай итеп, Муса әфәндене, бер яктан, гомере дәвамында казанган шөһрәте, дәрәҗәсе, танылуы коткарган булса, икенче яктан, әлбәттә, ышанычлы дусларының ярдәме хәлиткеч тәэсир ясый. Аның азат ителүенә, мөгаен, Ленин белән күрешеп сөйләшүе дә тәэсир иткән булырга мөмкин. Әмма төрмәдән чыгарылса да, Муса әфәнде хәрәкәт итү хокукыннан мәхрүм ителә һәм өч ел дәвамында Мәскәүдә сөргендә калу белән җәзалана. Делодагы кәгазьләрдә бу турыда болай диелә: *«Бигиев Муса Джарулла, 52 л., служитель религиозного культа. Обвинялся в распространении среди населения печатных произведений антисоветского содержания с целью дискредитирования Соввласти, кроме того в тесной связи с к-рев. группировками, что следствием установлено.*

*Постановлением Комиссии НКВД по адм. выс. от 1/II-24 г., Бигиев выслан в гор. Москву сроком на ТРИ года*[2]*».*

Шуның белән Бигиевкә каршы ачылган Дело архивка тапшырыла. Муса әфәнде белән бәйле следствие барган арада, 1924 елның башында ОГПУ исемен алыштырып, НКВД (Народный комиссариат внутренних дел) дип атала башлый. Бу

[1] Допрос протоколы. АСД. Л.75–76. Заключение.

[2] Допрос протоколы. АСД. Л.97.

йөздән Делодагы соңгы документта мөһер ОГПУ исеменнән түгел, НКВД исеменнән куелган. Моңа өстәп, кушымтада Муса Бигиевне гаепләү йөзеннән язылган «Заключение» исемле документның күчермәсе урнаштырылды[1].

Тикшеренү, сорау алу, протоколлар, әлбәттә, кешенең рухи халәтенә гаять тискәре йогынты ясый. Бу хәлләрдән Муса әфәнде дә котыла алмый. Делода сакланган бер протоколда мондый сүзләр бар: *«Моя мысль не работает, душа моя сильно тоскует о своих детях. И этим просто об'ясняются все недостатки и все грамматические ошибки, могущие оказаться в этих страницах...»*[2].

Делода иң тәэсирле документ, миңа калса, ире өчен ут йотып, аның янына Мәскәүгә ташланган Әсма ханыма язган бер кыска гына записка. Аның эчтәлеге турында сөйләп торуның хаҗәте юк, чөнки андагы беренче юллардан барысы да үзүзеннән аңлашыла:

*Вторая Мещанская № 28 кв № 1*
*Асьма Бигеевой*

*Милая моя Богиня!*

*Целую твои ноги, целую мою Фатиму.*

*Сижу в отдельной сухой большой камеръ. Пока не надо постели.*

*Доставь мне: чай, сахар, стакан, чайник, хороший сыр, мыло, домашний хлеб.*

*Со мною обращаются с большим вниманием. Не беспокойся.*

*Молись Богу, и все.*

*Твой раб: М. Бигеев.*

*14 ноября 1923.*

*Через секретаря Восточного отдела доставите все эти предметы продукты».*

---

[1] Карагыз: III Бүлек. 17: Заключение.

[2] Допрос протоколы. 1923 ел, 14 ноябрь. АСД. Л.27.

## Сөргендә. Галимҗан Ибраһимовның һөҗүме

Шулай итеп, 1924 елның башыннан Муса әфәнде Мәскәү тоткыны хәлендә өч ел дәвамында, ягъни 1927 елның февраль аена кадәр башкалада яшәргә мәҗбүр була. Муса әфәнде белән власть арасында булып алган әлеге конфликтны үз файдаларына әйләндерергә теләп, аны дошман күргән кайберәүләрнең теле чишелә. Андыйларның берсе совет идеологиясен тулысынча кабул иткән Галимҗан Ибраһимов (1887–1938) була. Үзенең 1924 елгы татар әдәбиятында марксистик-ленинчыл методологияне куллануга багышланган «Кара маяклар, яки Ак әдәбиятлар» исемле мәкаләсендә ул Муса Бигиевнең 1920 елда Төркестанга барып, андагы халыкны Совет властена каршы көрәшкә күтәрергә теләгәне һәм бу эштә Бөекбритания премьер-министры Ллойд Җорҗдан ярдәм сорап Күлҗәдәге илче аркылы аңа хат тапшырырга ниятләгән мәлдә кулга алынуы турында язып чыгып, аңа яла яга. Әмма чынлыкта ул хатны тапшыру бөтенләй башка кешеләргә йөкләнгән булып, Муса әфәнде ул авантюрада катнашмаган. Галимҗан Ибраһимовның Муса әфәндегә һөҗүм итүенең сәбәпләре тирәнгә китә. Аның башы, миңа калса, 1914 елда Муса әфәнденең *«Халык назарына берничә мәсьәлә»* исемле китабында Г. Ибраһимовның дәреслекләренә тәнкыйть сүзләре әйтүенә барып тоташа. Галим Ибраһимовның дәрес китапларына түбәндәге бәя биргән:

*«Галимҗан әфәнде Ибраһимовның ике китабында[1], аеруча сарыф өлешендә, рус грамматикаларына начар рәвештә тәкълидтән башка бер мәгънә мин күрмәдем.*

*Кулланган истыйляхләре[2], яңа сүзләре, күбесенчә, катгый сурәттә хатадыр. Сарыф вә нәхү китаплары яза торган каләм хакында гафу кылынмаслык хаталар, – тел хаталары белән бәян хаталары да, – бу ике китапта аз түгелдер. Бу ике*

[1] Әлеге ике китап: «Татар сарыфы». Казан: И. Н. Харитонов матбагасы, 1911. 82 б.; һәм «Татар нәхүе». Казан: И. Н. Харитонов матбагасы, 1911. 74 б.

[2] истыйлях – нинди дә булса фәнни төшенчәне белдерә торган сүз; термин.

*затның*[1] *китаплары шәкерт теле белән, ученик каләме белән, тәкълид фикере белән язылган булса кирәк.*

*Телнең үзеннән, рухыннан, сарыф вә нәхүнең файдасыннан, максатыннан хәбәре булган каләм мондый сарыф вә нәхү буенча китаплар язмас. Шундый бер караш, мөгаен, бары тик миңа гына хастыр. Ләкин минем карашым, һәрхәлдә, шушыдыр*».

Соңрак заманнарда да Муса әфәнде белән Г. Ибраһимовның кайбер сәяси һәм мәдәни мәсьәләләргә карата карашлары төрле була.

Ул елларда властьның, Муса әфәндегә басым ясап, аны, Совет хакимиятен хуплап, ирексез сурәттә бер мәкалә язарга мәҗбүр иткәне мәгълүм. Бу хат 1925 елда Һиндестан Хилафәт комитеты раһбәре Мөхәммәт-Гали Җәһүр[2] исеменә язылып, «Bombay Chronicle» гәзитенең 1 октябрь санында басылып чыга. Анда мондый сүзләр әйтелә: *«Залим идарә урынына гадел бер хакимият корылды. Эшче сыйныфлар әсирлек богауларыннан котылды, авыл халкы җирбиләүчеләрдә тоткынлыктан чыктылар, рәхимсез мөгамәләгә тартылган, барлык халыклар бозылган эксплаутация низамы юкка чыгарылды, бөтен кавемнәр арасында тигезлек нигезләре салынды, кеше хокуклары урнаштырылды. Нәтиҗәдә, барлык диннәр иректә һәм мөхтәрәмдер. Һәр иҗтимагый оешма үзара хәл ителә торган мәсьәләләрне чишүдә иректә һәм үз ихтыярында булган идарәләргә иядер. Без – мөселманнар өчен, бу илдә барлык эшләребездә, иҗтимагый, әхлакый, дини бөтен эшчәнлегебездә тулы иминлек бар. Без Бөек революциянең нәтиҗәләреннән файдаланабыз. Әгәр файдалануыбыз тулы түгел икән, бу безнең матди һәм рухи үсешебез ноктасыннан*

---

[1] «ике зат» – Муса әфәнденең тәнкыйте ике авторның хезмәтләренә карый, аларның тагын берсе – Гыймад Нугайбәк.

[2] Мөхәммәт Гали Җәүһәр (1878–1931) – Һиндестан мөселман эшлеклесе, БөтенҺиндестан Мөселман Лигасының күренекле әгъзасы, журналист һәм шагыйрь, хәрәкәтнең әйдәп баручы эшлекләләреннән берсе; Хәлифәт мәсьәләсе Мөхәммәд Гали Җәүһәр эшчәнлегенең үзәгендә торган.

*алга таба үсешкә этәрә. Революция башланганнан алып, бүгенге көнгә кадәр мин революционерлар тарафыннан нәшер ителгән иҗтимагый, сәяси һәм фәлсәфи әсәрләрне укып барам. Мин бу бөек һәм якты революцион хәрәкәт тарафыннан таратылган гыйлем һәм фәннәрдән күп файда күрүем һәм канәгатьлелек кичерүем, бу гыйлем һәм фәннәрнең Бөек Коръәннән дә могъҗизалырак һәм ислам кануннарыннан гаять мөкәммәл булуына шаһитлык итәм. Коръәндә булган тәгълимат вә мәгълүматны тәфсилләп ача*».

Әлеге мәкалә Муса әфәнденең фикердәшләрен аптыраштa калдыра, әмма алар аның кылыч астыннан язылганын аңлыйлар булса кирәк. Муса әфәнденең Совет хакимиятен бу кадәр күккә чөеп мактавы бу сүзләрнең, асылда, ясалма булуын, ирексездән әйтелгән булуын үзе үк фаш итә. Шулай да, хакимияткә баш июдән гыйбарәт булган бу адымның да үзенә күрә файдасы була, чөнки ул хат язылмаган булса, Муса әфәндегә 1926 елда үткәрелгән Хилафәт корылтаена барыр өчен юл ачылмаган да булыр иде, мөгаен.

Сөрген тоткыны булуга карамастан, Муса әфәнде шактый иркле шартларда яши. Мәсәлән, 1925 елда ул Кырымга барып ял итәргә рөхсәт алуга ирешә, ә 1926 елда Совет хөкүмәте аңа Каһирәдә үткәреләсе Беренче Хилафәт корылтаенда катнашырга рөхсәт бирә. Хилафәт корылтаена кадәр Муса әфәндәнең Кырым сәфәренә туктап алыйк. Бу ярымутрауда үткәргән вакытын Муса әфәнде, бәлки, ялга багышлар иде дә, әмма мәшһүр дин галименең киләчәге турында хәбәр алган Кырым дин әһелләренең планнары башка булган. Нәтиҗәдә, Кырымда Муса әфәнде үзенең ***«Шәригать исламия назарында мөскират мәсьәләләре»*** (***«Мөскират»***) исемле әсәрен яза башлый.

Китап Кырым һәм Төркестан мөселманнарының үтенечләренә җавап бирү йөзеннән, шәргый фәтва буларак язылып, ахырда бөтен төркиләрнең хөкемнәренә, тәнкыйтьләүләренә һәм файдалануларына тәкъдим итү теләге белән, дини бер рисалә шәкелендә нәшер ителгән була. Чыннан да, Кырым мөселманнары Муса әфәндегә шәригать күзлегеннән караган-

да үтә дә кискен, бәхәсле һәм җитди сораулар куялар. Һич тә тартынмыйча шуны әйтеп була: танылган дин галименең ул сорауларга бирәчәк җаваплары кырым татарлары өчен яшәү белән үлем мәсьәләсе диярлек әһәмияткә ия була. Бу җавапларны үз эченә алган *«Мөскират»* гәрчә бераз соңрак – 1927 елда басылып чыкса да, Муса әфәнде үзенең җавапларын, дөресрәге, шәригать фәтвасын, 1925 елда, ягъни Кырымда дин кардәшләре белән аралашкан вакытта ук яңгыраткан. Кушымтада аның кереш сүзе китерелде[1]. Биредә исә китапта *«Бу заманның яшь шәкертләренә минем берничә киңәшем»* исемле шәкертләргә аталып язылган бер бүлекчәне китерербез:

*«1) Бөтен мәзһәбләрнең фикъһы китапларын, шөкер теле белән әйтим, мин дә укыдым. «Кыйлә»ләрен дә, «калә»ләрен[2] дә күрдем. Аларның һәрберен һәр адәмнән күбрәк өйрәндем дә, кабул да иттем. Бөек мөҗтәһидләрнең бәрәкәтле иҗтиһатларыннан да илһам алып, хаҗәт булса, мөмкинлек килеп чыкса «культу»ларымны да, «кульна»ларымны да[3] китапларым сәхифәләрендә язармын, иҗтиһат минбәрләрендә әдәплелеккә чакыручы тел белән бәян итәрмен.*

*Болай булу сезнең дә, минем дә мөкаддәс изге хокукыбыздыр. Бәлки бүген хәтта фарыз гайн[4] булып калган бер вазифабыздыр.*

---

[1] Карагыз: III Бүлек. 18: «Мөскират» китабыннан: Сүз бисмилласы.

[2] «Кыйлә» («әйтелгән»), «калә» («әйткән») – биредә дини китапларда, аерым алганда рәддия (кире кагу), шәрех һәм хәшияләрдә китерелгән мәгълүматны бәян итү тәртибе күздә тотыла. Мәсәлән, берәүнең элегрәк язылган әсәренә аңлатма яки рәддия язарга алынган башка бер галим сүзен: «Фәлән болай дигән (калә)…», яки «Болай диелгән (кыйлә)…» рәвешендә китерә дә, үзенең шул әйтелгәннәргә кагылышлы фикерен бәян итүгә күчә торган булган.

[3] «Культу» («мин әйттем»), «кульна» («без әйттек») – югарыда китерелгән мәгълүмат бирү алымның тагын бер калыбы күздә тотыла, мәсәлән, «Фәлән болай дигән, мин исә болай дип әйттем…».

[4] фарыз гайн – һәр мөселман шәхсән үзе үтәргә тиешле булган фарыз гамәл.

*2) Һәр көн, һәр төн намазларның һәрберендә, һәрбер рәкәгатендә бөтен өммәтнең ихласлы «**иһдина-с-сырата-л-мөстәкыйм**»[1], дигән догасының көннәрнең берендә кабул булуы өмет ителсә, Шәригъ хәким хәзрәтләренең[2], гөнаһсыз фәрештәләрнең «Амин!» кыйлган вакытларының берендә җавап килә алса, кабул минутлары, җавап алу сәгатьләре нәкъ менә бу вакыттыр.*

*3) Иҗтиһат юлларында иһтида[3], гыйлем эстәү, җавап эзләү юлларында бөек мөҗтәһидләрнең әдәпләренә иярү ул намаз догаларының, «әл-Фатиха» догаларының бөек бәрәкәтле нәтиҗәләредер.*

*Болай булмаса әгәр, ягъни иҗтиһат һидаяте[4] өммәт исламиядә булмаса, бөек мөҗтәһидләр кебек, иҗтиһат әдәпләре бүген бездә булмаса, гасырлар буенча бөтен өммәтнең ихласлы догасы (وَمَا دُعَاء الْكَافِرِينَ إِلَّا فِي ضَلَال)[5] булып калыр.*

*4) Коръән кәрим Гареше хакыйкатьтән[6] безнең калебебезгә иңде. Пәйгамбәрлек тәгълиматы бәлагать[7] теле белән безнең калебебезгә тулды. Безнең фикерләребезнең мигъраҗлары өчен, хәрәкәтләре өчен күкләрнең киң капулары ачылды. Шуннан бирле күкләрнең бөтен яктылыгын калебебез, җирләрнең бөтен нурларын акылыбыз кабул итеп тора.*

---

[1] «Безне тугры юл буенча алып бар» (Коръән кәрим, 1:5).

[2] Шәригъ хәким хәзрәтләре (Канун булдыручы хикмәт иясе хәзрәтләре) – Муса әфәнденең китапларында әлеге гыйбарә контекстка күрә Аллаһны да, Аның илчесен дә белдерә ала.

[3] иһтида – биредә: дөреслеккә ирешү, дөрес чишелешне табу. Әлеге сүз «Фатиха» сүрәсендәге иһдина (безгә һидаять кыйл, ягъни, безне ияртеп бар; безне тугры юлга чыгар) фигыле белән бер тамырдан ясалган. Шуны күздә тотып автор биредә иһтида сүзен аңлы рәвештә куллана һәм адәм баласы кыйлган догалар нәтиҗәсендә илаһи һидаятьнең гамәлгә ашуын ассызыклый.

[4] һидаять – тугры, дөрес юлдан алып бару.

[5] «Кяферләрнең (Аллаһны кире кагучыларның) догалары юлдан язудан башка берни дә түгелдер» (Коръән кәрим, 40:50).

[6] Гареш-е хакыйкать – Хакыйкать тәхете.

[7] бәлагать – матур, төзек, үтемле, тәэсирле сөйләм; красноречие.

*Шуңа күрә һәр хосуста дөреслек шәрәфләре*[1] *безнең хокукыбыздыр. Бөтен әһле исламның мөкаддәс изге хокукыдыр.*

*Соңгы дүрт җөмләмне мин биредә урынлы булыр дип өммәт исеменнән, фитъралары*[2] *саф булган милләтебез балаларының пакь рухларына, яшь миләренә үтеп керсен өчен яздым.*

*Заманыбызың яшь шәкерт-таләбәләренә*[3]*, белемгә омтылган мөгаллимләренә, мәчетләрнең тырыш һәм эшлекле имамнарына, оста һәм үтемле телле хатыйпларына минем киңәшем кебек бер нәрсә булыр.*

*Әдәби, иҗтимагый һәм, бәлки, сәяси инкыйлабның иң зарур, иң асыл нигезләре, безнеңчә, әлбәттә, будыр*».

Шәкертләр дигәндә, Муса әфәнденең гомер буе – туган илендә дә, горбәтлектә дә – аннан белем эстәп килгән шәкертләргә гарәп теле һәм гарәп теле теориясе, гарәп шигърияте һәм аның теориясе, дин гыйлемнәре буенча шәхси дәресләр биргән булуын да онытырга ярамый. Аның кулы астында белем алган яки аны камилләштергән кешеләр арасында зур галимнәр булып җитешкәннәре дә аз түгел. Мәсәлән, инде искә алынган Әхмәт-Зәки Вәлиди белән Баттал-Таймас кебек тарихчы вә Шәрык әдәбияты белгечләре. Моннан тыш, 20 нче елларның икенче яртысында Муса әфәндедә сабак алган Закир углы Мөхәммәт-Бакый Халидов (1905–1968) белән аның авылдашы Таһир углы Габдерахман Таһирҗановны (1907–1983) искә алмыйча узарга ярамый.

Хәзерге Татарстанның Апас районындагы Морза авылында туган Мөхәммәт-Бакый Халидов Буа мәдрәсәсендә дини белем ала, соңыннан Ленинрадка барып чыгып, анда Муса әфәнде белән таныша, аңардан белем ала, Баку, Ашхабад шәһәрләрендә эшли, 1941 елда Казан дәүләт университетының физика-математика факультетын тәмамлап, Ташкент обсерваториясенә эшкә озатыла, әмма шул ук елда сугышка

[1] шәрәф – мәртәбә, кадер; честь.

[2] фитъра – һәр адәм баласына тумыштан бирелгән хакыйкый иман ералгысы, Аллаһы тәгаләгә тартылуның, Аны тануның башлангычы.

[3] таләбә – студентлар.

алына һәм Иранда хәрби тәрҗемәче булып хезмәт итә. Сугыштан соң, Ташкент университетының гарәп филологиясе кафедрасына нигез сала, Үзбәкстанда Көнчыгышны өйрәнү фәнен торгызуга зур өлеш кертә, Советлар Союзының лингвистик югары уку йортларда киң кулланылыш тапкан гарәп теле дәреслеген яза. Ул дәреслек буенча Советлар Союзының берничә буын гарәп теле белгечләре укып белем ала.

Габдерахман Таһирҗанов мәдрәсәдә чагында ук Коръәнхафизлыкка ирешә, авылдашы Мөхәммәт-Бакый Халидов белән Ленинградка китә, шулай ук Муса әфәндедә укый. Бу укуның никадәр киеренке булуын Фатыйма ханымның хатирәләре аңларга ярдәм итә. Фатыйма ханым болай дигән: «Әти исә Габдерахманга иртәдән төшкә кадәр өендә гарәп телен укыткан». 1946 елда Котбның «*Хөсрәү вә Ширин*»е буенча диссертация яклый һәм Ленинград университетының шәрык факультетында фарсы теле укыта башлый, шул ук вакытта Шәрыкне өйрәнү институтында эшли, илебездә классик фарсы әдәбияты буенча иң зур белгечләрнең берсе булуга ирешә, 1969 елда Рудаки шигъриятенә багышланган докторлык диссертациясен яклый. Габдерахман әфәнде Муса әфәнденең кече кызы Фатыймага өйләнеп, олуг галим белән туганлаша.

***

1924 елда Төркиядә чыккан «Сәбилерришад» журналы Муса әфәнденең төрмәгә утыртылуына сәбәп булган «*Исламият әлифбасы*»ннан аерым бүлекләрне үзенең сәхифәләрендә бастырып чыгаруны дәвам итә. Шулай итеп, гыйнвардан март аена кадәр чыккан саннарда:

«*Гомуми әсасләр: Муса Җаруллаһ әфәнденең большевикларча мөҗибе тәүкыйфы олан китабындан*»[1] («Гомуми нигезләр: Муса Җаруллаһ әфәнденең большевиклар тарафыннан кулга алынуының сәбәбе булган китабыннан»);

---

[1] Гомуми әсасләр: Муса Җаруллаһ әфәнденең большевикларча мөҗибе тәүкыйфы олан китабындан // Сәбилерришад. 3 январь 1924. 23 т., 582 сан. С. 151.

*«Әһле исламның тәгаруфы хакында маддәләр: Муса Җаруллаһ әфәнденең большевикларча мөҗибе тәүкыйфы олан китабдан»* (*«*Әһле исламның үзара танышып-белешеп торулары хакындагы маддәләр: Муса Җаруллаһ әфәнденең большевиклар тарафыннан кулга алынуының сәбәбе булган китаптан»);

*«Бу гүнүн мөһим хаҗәтләренә даъир тәдбирләр»*[1] (*«*Бүгеннең мөһим хаҗәтләренә караган чаралар»);

*«Мөхарәбә хәлләренә даъир Муса Җаруллаһ әфәнденең большевикларча мөҗибе тәүкыйфы олан китабындан»* (*«*Сугыш хәлләренә карата») исемле мәкалә, һәм шулай ук март аенда *«Кадынын хокук вә вазаъифенә даъир: Муса Җаруллаһ әфәнденең большевикларча мөҗибе тәүкыйфы олан китабдан»* (*«*Хатын-кызның хокуклары һәм вазифаларына карата») исемле мәкаләләр басыла.

## 1926 ел: Бөтендөнья мөселман корылтайлары

Инде 1926 елда Каһирәдә үткәреләсе Бөтендөнья мөселман корылтае һәм бу сәяси вакыйгага бәйле булган иҗтимагый һәм халыкара сәяси реакциягә килик. Муса әфәндегә бу олы чарада катнашырга рөхсәт бирелүенең нинди әһәмияткә ия булуын аңлар өчен, корылтай турында да, ул дәвердәге сәяси вазгыять турында да, һичшиксез, тулырак мәгълүмат бирергә кирәк.

1922 елда, Госманлылар империясе белән бергә Хилафәтнең дә юкка чыгарылуыннан соң, мөселманнар яңа Хилафәт канаты астында берләшеп яшәү теләген белдерә башлыйлар. Мисырда, Сүриядә, Филистыйнда, Фарсыстанда, Гарәпстанда, Төркиядә, Кәшкарда һәм, хәтта, Советлар Союзында да мөселман җәмәгатьчелеге әлеге проблеманы бәхәс үзәгенә куеп, яңа хәлифә сайлау һәм Хилафәтнең язмышын хәл итү турында ныклап уйланалар. Мәсәлән, Бөекбритания импе-

[1] 28. Ehl-i İslam'ın Tearrüfü Hakkında Maddeler (Musa Carullah Efendi'nin Bolşeviklerce Muceb-i Tevkifi Olan Kitaptan); Ehl-i İslam'ın Birliği Hakkında Maddeler. Belirtilmemiş Sebilürreşâd Bildiri 6 Mart 1924 23. Cilt 591. Sayı 303. Sayfa

риясенең колониясе булган Һиндестанда җирле мөселманнарның сәяси хәрәкәтен җитәкләүче Һинд хилафәт комитеты оештырыла. Ә Муса әфәнде Бигиев Хилафәткә кагылышлы фикерләрен инде 1923 елда ук «*Ислам милләтләренә*» исемле китабында бәян иткән була.

Хилафәт мәсьәләсен чишүдә империалистик державаларның катнашуын да истә тотканда, бу мәсьәлә глобаль проблемага әверелә. Планета кимәлендәге бу дини-иҗтимагый ихтыяҗны тоеп, Бөекбритания хөкүмәте тулысынча үзенең кулы астында булачак яңа Хилафәт төзү мәсьәләсен үзенең тышкы сәяси көн тәртибенең үзәгенә куя. Шул рәвешле Хилафәт мәсьәләсен хәл итәргә тиешле Бөтендөнья мөселман Корылтаен үткәрү мәсьәләсе кузгатыла. Бу эштә һәркайсы үз мәнфәгатьләрен кайгыртып Бөекбритания, Франция һәм Советлар Берлеге дә актив катнашалар. Гомумән алганда, XX гасырның 20 нче елларында Совет хөкүмәте Якын Көнчыгышта үзенең сәясәтен үткәрү өчен совет мөселман дин әһелләрен актив кулланган була. 1924 елда Советлар Союзы Хиҗаз корольлеге белән дипломатик мөнәсәбәтләр корып, Җәддәдә дипломатик миссия ачып җибәрә.

1926 елның 10 гыйнварында Сөгыд нәселеннән булган Габделгазиз Хиҗазның элекке мәлиге Хөсәен ибне Гали, әл-Һашимине берничә ел дәвамында барган сугыш нәтиҗәсендә җиңеп, үзен Хиҗаз, Нәҗед һәм Көньяк биләмәләрнең мәлиге (короле) дип игълан итә. Яңа мәмләкәт барлыкка килер-килмәс борын, ягъни 16 февральдә Советлар Берлеге хөкүмәте Ибне Сөгыдне рәсми рәвештә король буларак таный. Совет дипломатиясенең вәкаләтле вәкиле (полномочный представитель) буларак Ибне Сөгыд белән мөнәсәбәтләр кору милләттәшебез, кайчандыр «Хөсәения» мәдрәсәсе шәкерте булган татар егете Габдерәүф угълы Кәрим Хәкимовка йөкләнә.

Кәрим Хәкимовның шәкерт чагында Муса әфәнде белән күрешкән булуы ихтимал, чөнки ул 1908–1910 елларда «Хөсәения» мәдрсәсендә укыган була. Соңрак дәвердә язмыш аны Совет иленең дипломатик даирәләренә китерә. 1924 елдан башлап, Кәрим Хәкимов Советлар Союзының Хиҗаздагы

вәкаләтле вәкиле вазифаларын башкара. Ул чакта Хиҗазның мәлиге (короле) булып пәйгамбәр нәселеннән Хөсәен ибне Гали әл-Һашими торган. Гарәп дөньясында Советлар Союзының беренче дипломаты булган Кәрим Хәкимов тырышлыгы белән алга таба Сөгуд Гарәбстаны СССРның стратегик партнеры дәрәҗәсенә күтәрелә, совет товарлары өчен Гарәбстанга һәм Якын Көнчыгышка юл ачыла. Тарихчы Р. Вәлиев язуынча, нәкъ менә К. Хәкимов тырышлыгы белән, Одесса һәм Җәддә арасында хаҗилар өчен пароход рейслары оештырыла. Сүз уңаеннан әйтергә кирәк, Муса әфәнде үзенең 1927 елгы хаҗнамәсендә әлеге Одесса-Җәддә пароход юлының уңайлыкларын хуплап телгә ала.

Талантлы дипломат Кәрим әфәнде Хәкимовның бәрәкәтле хезмәте ярдәмендә Советлар Союзы белән дустанә мөнәсәбәтләр оештырган Ибне Сөгыд Якын Көнчыгышта үзенең сәяси уенын алып барган Бөекбритания өчен бик үк ятышлы илбашы булмый, әлбәттә. Англиянең дөньяның бу төбәгендәге асыл максаты үзенең сәяси-экономик тәэсирен саклап калу һәм үстерү була. Бөекбритания колониаль идарәсе әһелләре, мөселманнарның берләшү омтылышларын үз илләренең мәнфәгатьләре өчен файдаланып, шул омтылышның сәяси җимешләрен, ягъни барлыка килә алган структураларын үзләренең ихтыярларына буйсындырырга тырышалар. Шуңа күрә Лондон Гарәп ярымутравында үзенә тугры булган берәүне хәтта яңа хәлифә итеп тә игълан итәргә әзер була. Әмма Кәрим Хәкимов Бөекбританиянең бу планнарын боза. Нәтиҗәдә олы державалар арасында Бөтендөнья мөселман корылтаен үткәрү урыны турында бәхәс куба. Бу шартларда Лондон Мисырның үзенә буйсынган дин әһелләре аркылы Конгрессны Каһирәдә үткәрү идеясен алга сөрә. Әмма дөнья мөселманнарының күпчелеге бу тәкъдимне хупламыйлар. Аерым алганда, Һиндестан һәм Советлар Союзы мөселманнары бу фикергә кискен төстә каршы чыгалар. Мәсәлән, 1926 елда мөфти Ризаэтдин Фәхретдин СССР хөкүмәтенә: «Корылтай империалистик дәүләтләрнең тәэсирендә булмаган илдә үткәрелергә тиеш»,– дигән телеграмма суга. Шунда ук Риза

хәзрәт Корылтайны инглизләр карамагында булган Мисырда һич тә үткәрергә ярамаганын ассызыклый. Әлеге киңәшләргә таянып булса кирәк, Совет хөкүмәте Корылтайны һәр мөселман өчен изге булган һәм Кәрим Хәкимов тырышлыгы белән Мәскәүгә якынаеп өлгергән Ибне Сөгыйд кулы астындагы Мәккәдә үткәрүне хуплап чыга.

Мондый вариант Англия белән Франциячне, әлбәттә, канәгатьләндерми. Әлеге ике илнең Якын Көнчыгышта тәэсире Советлар Берлегенекеннән күпкә зуррак булганга күрә, Бөтендөнья мөселман корылтае (аны шулай ук Каһирә хилафәт корылтае дип тә атыйлар) үзенең эшен 1926 елның 14 маенда Мисырның башкаласы Каһирәдә башлый. Бу чараның максаты – Англиягә буйсындырылган бөтендөнья мөселман оешмасын барлыкка китерү булган. Корылтайны оештыру комитеты, мөселманнарны Корылтайда катнашырга дәгъвәт итеп, бөтен мөселман илләренә, шул исәптән Советлар Союзының Уфа Диния нәзарәтенә гомуми чакыру һәм, аерым алганда, Муса Бигиевкә шәхси чакыру юллаган була[1]. Әмма Корылтайга әзерләнү процессын игътибар белән күзәтеп торган инглизләр, оештыру комитетының теләгенә каршы чыгып, Муса әфәндегә Мисырга килергә рөхсәт бирмиләр[2]. Ахыр чиктә, Каһирә Корылтаена нибары 25-ләп делегат килә һәм, кворум булмавы сәбәпле, аның карарлары дөнья мөселманнары күзендә юридик көч казана алмыйлар. Ягъни, формаль сурәттә Каһирә корылтае үткәрелсә дә, ул нәтиҗәсез була.

Мөселман корылтаеның Каһирәдә үткәрелүенә ризасызлык күрсәтү йөзеннән 1926 елның 7 июнендә Мәккә мөселман Корылтае үз эшен башлый. Бу Корылтайга рәсми төстә Советлар берлеге мөселманнары да катнашалар. Советлар Берлеге (СССР) мөселманнарының вәкилләре ошбу шәхесләр була: Уфа Диния нәзарәте мөфтие Ризаэтдин Фәхретдин;

---

[1] Карагыз: Сов.секретно о халифатском конгрессе https://islamperspectives.org/rpi/items/show/16772

[2] Карагыз: Ислам и мусульмане по материалам восточного отдела ОГПУ. 1926 год.– Документ № 10 http://www.idmedina.ru/books/islamic/? 1402

мөфти урынбасары Кәшшафетдин Тәрҗемани; Мәскәү шәһәре мөселманнары вәкиле Муса Җаруллаһ; Хаҗитархан (Әстерхан) мөселманнары вәкиле Габдрахман Гомәри; Татарстан АССР дин әһелләре вәкиле Таһир Ильяси; Кырым мөфтие Мөслихетдин Хәлил; Петропавловск мөселманнары вәкиле Мәһди бин Мәгъкуль; Ташкент Диния нәзарәте вәкиле Габделвахид әл-Кари. Корылтайны үткәрүчеләр Муса әфәндегә аның үз исеменә язылган махсус дәгъвәтнамә белән мөрәҗәгать итәләр. Гаҗәп, әмма Совет хөкүмәте сәяси сөрген хәлендә булган Муса әфәндегә Мәккәгә барырга рөхсәтен бирә.

Советлар Союзы мөселманнары делегациясе, 1926 елның 6 маенда юлга чыгып, бер айдан Хиҗазга барып җитә, ә 1926 елның 7 июнендә Мәккәдә Мөэтәмәр ислами (Ислам корылтае) ачыла. Корылтайда 57 делегат катнаша. Аның эшен 157 чакырылган кунак һәм матбугат вәкилләре күзәтеп тора. Әмма корылтайның бу көннәрендә Муса әфәнде делегатлар арасында булмый. Корылтай протоколларыннан күренгәнчә, Мәккәгә Муса әфәнде Төркия делегатлары белән бергә егерме көнгә соңарып килеп төшә[1]. Димәк, Муса әфәнде өч атнага якын вакытын Истанбулда, шул җөмләдән югарыда искә алынган «*Мөскират*» исемле китабын бастыру мәшәкатьләренә багышлап үткәргән була. Ул җирле матбугат чараларына интервью бирә, Истанбулда яшәгән дуслары белән күрешергә вакыт таба. Аерым алганда, Зәки-Вәлиди Тоган 1926 елда Истанбулда Муса әфәнде белән күрешүе турында истәлекләрендә язган[2]. Баттал-Таймасның язуынча, аның да Муса әфәнде белән очрашуларыннан берсе 1926 елның язында Истанбулда була: «*Бу [очрашу] Истанбулда булды. Шул елның язында [ягъни 1926 елда] хәзрәтебез Истанбулның Чагалоглыдагы Җәридәханә урамындагы Габдерәшит Ибраһимның*

[1] Карагыз: Сотрудничество советской дипломатии и мусульманского духовенства СССР в 20 – е годы XX века http://www.idmedina.ru/books/islamic/? 3971

[2] Заки Валиди Тоган. Воспоминания. Борьба народов Туркестана и других восточных мусульман-тюрков за национальное бытие и сохранение культуры. Книга I. Уфа: «Китап», 1994. С. 344.

*кызы өендә очраштык. Чәй эчтек*». Габдерәшит Ибраһимның искә алынган кызы – Фәүзия ханым Ибраһимова (төрек фамилиясе Догрул)[1]. Шул чәй мәҗлесендә Баттал-Таймас Муса әфәндедән аның 1925 елда «Bombay Cronicle» гәзитендә Совет хакимиятен хуплаган сәер мәктүбенең язылуы сәбәбе турында сорый. Муса әфәнде ул мәкаләнең чекистларның басымы астында язылган булуын әйтә.

Муса әфәнде Корылтай эшенә аның унынчы утырышында кушыла. Бу утырыш 1926 елның 27 июнендә үткәрелә, анда Төркиядән, Әфганстаннан, Йәмәннән килеп җитешкән яңа делегацияләр катнаша. Яңа килгән делегатлар (шул исәптән Муса әфәнде дә) котлау сүзләре белән чыгыш ясыйлар. Муса әфәнде мондый сүзләр әйтә:

«*Мин хөрмәтле рәисне һәм хөрмәтле делегатларны сәламлим.*

*Биредә мин Русиянең утыз миллионнан ашкан ишле мөселман халыкларын тәкъдир итү шәрәфендәмен. Алар Корылтай үз вазифасын башкарыр дип, шул исәптән изге урыннарның халәтен яхшыртыр дип һәм мөселман дөньясының бәйсезлеген ныгытыр дип өметләнеп торалар. Дәгъвәтнамә кулыма килеп кергәннән соң мин илемнән беренче булып чыгып киттем һәм иң соңгы булып бирегә килеп кердем. Әмма мин бирегә иң зур ислам дәүләте булган Төркия делегациясе белән бергә килүемә бик бәхетлемен. Мин Корылтайда да, хаҗда да катнашырга бик теләгән идем, тик Мисыр хөкүмәте, мөселман булса да, миңа каршы киртәләр корды*»[2].

Корылтай эшен тәмамлаганнан соң, Советлар берлегеннән килгән делегатлар, шул исәптән Муса әфәнде дә ватаннарына

---

[1] Җәридәханә урамындагы 5 номерлы йортта Габдерәшит-хәзрәт Ибраһимның кызы Фәүзия-ханым Догрул (Ибраһимова) (1887–1985) яшәгән. Аның турында тулырак: Хайрутдинов А. Г. Общественная деятельность Фаузии Ибрагимовой. Minbar. Islamic Studies. 2022; Т. 15 (№ 2); Б.303–324.

https://www.minbar.su/jour/article/view/1097/625

[2] Татар теленә урысчадан тәрҗемә. Чыганак: http://www.idmedina.ru/books/islamic/? 3975

кайталар. 1927 елда «Ислам мәҗәлләсе»[1] журналында Ризаэтдин хәзрәт, Бөтендөнья мөселман корылтаена Советлар Берлегеннән барган делегациянең җитәкчесе буларак, ул чара турында отчет бирә. Ә аңарчы 1926 елның декабрь санында Муса әфәнде Шәһәр Шәрәф белән автордашлыкта «Иптәш Сталинга» исемле бер хат бастыра. Аның эчтәлеге, табигый ки, мөселманнарның властька теләктәшлек итүләрен күрсәтүне күздә тота:

«*Уфа шәһәрендә булып үткән Мөселман руханилары вә мәхәллә вәкилләренең нәдвәсе*[2] *үзенең ябылуы алдыннан сезгә ялкынлы сәламен юллый, юксыллар вә элекке Русияда яши торган халыкларның капитал золымыннан вә патша истибдадыннан*[3] *тәмам котылуларына тугыз ел тулу мөнәсәбәте белән сезнең затыгыз аркылы Октябрь инкыйлабы юлбашчыларын, ислам галәме, куәтле инкыйлабның беренче көненнән алып, сезне мәзлум халыкларны ирекккә чыгаручы вә Шәрык халкы ихтыяҗларына нык бaгланучы дип белә. Нәдвә мәзлум халыкларны вә юксылларны азатлыкка чыгару юлындагы эшегезне чынлыкка ирештерер өчен, сезгә куәт вә гайрәт таләп кыйла. Яшәсен ирекле кешенең дөньясы!*»

## Муса әфәнденең хаҗга баруы. Куен дәфтәрләре

1927 ел илдә ислам диненә каршы көрәшнең кисәк кенә көчәеп киткән дәвере була. Бөтен ил буйлап мәдрәсәләр ябыла, мәктәпләрдә укыту программалары үзгәртелеп, динсезлекатеизм нигезенә күчереләләр. 1930 елгача мөхтәсибәтләрнең йөздән сиксән җидесе, мәчетләрнең йөздән җитмеше ябыла һәм «дин калдыклары» учаклары итеп игълан ителгән мә-

---

[1] «Ислам мәҗәлләсе» – Эчке Русия һәм Себер мөселманнары Диния нәзарәте (ЦДУМ) тарафыннан чыгарылган татар телле дини-әхлакый һәм фәлсәфи журнал. 1924–1928 елларда Уфада ике айга бер мәртәбә чыгарыла. 1926 елдан «Ислам» исеме белән нәшер ителә башлый. Русиядән тыш, саннары Урта Азия Совет республикаларында һәм чит илләрдә таратыла.

[2] нәдвә – җыен.

[3] истибдад – изү.

четләр җимертелә. Мулла вә мәзиннәрнең барысы да диярлек дини эшчәнлекләрен алып барудан мәхрүм ителәләр, өйләреннән куылып гаиләләре белән Себергә сөреләләр; илдә чыгып килгән бердәнбер ислам журналы булган «Ислам»ның башта тиражы конфискацияләнә, ә 1928 елда журнал үзе дә ябыла.

Шул дәһшәтле елның башында Муса әфәнденең сөрген җәзасы вакыты тәмамлана да ул гаиләсе янына Ленинградка кайта. Шул ук елның май аенда хаҗ йоласын үтәү нияте белән янә ерак юлга чыга. Муса әфәнденең 1927 елда кылган хаҗ сәфәре турындагы язмалары, аның куен дәфтәрләрендә сакланып, Аллаһның теләктәшлеге вә дусларыбызның ярдәме белән безнең кулга да килеп керде. Муса әфәнденең куен дәфтәрләре аның тормыш юлын өйрәнүдә, гыйльми эшчәнлегенең алымнары һәм уй-фикерләре белән танышуда зур ярдәм күрсәтә алырлык чыганак булып торганга күрә, бу хакта беразкүбрәк мәгълүмат бирү дөрес булыр.

Туган якларыннан китеп, ил буйлап яки чит илләрдә сәяхәт кылган кешенең юлда күргәннәрен, шул күргәннәрдән туган тәэсирләрен кәгазьгә теркәп баруы – борынгыдан килгән матур гадәт. Муса Бигиев тә үзенең сәфәрләрен, куен дәфтәрләрендә чагылдырып, язып-беркетеп барган. Галимнең куен дәфтәрләре төрле калынлыкта һәм зурлыкта булган 27 дәфтәрдән гыйбарәт. Араларында мәктәпләрдә кулланыла торган 12 битле гади язу дәфтәрләре дә, шактый күп сәхифәле, мәсәлән 86 битле катыргы тышлыклы блокнотлар да бар. Күчермәләр арасында Советлар Союзында басылган мәктәп дәфтәрләре дә, Кабул, Дәһли белән Бомбей, Тәһран вә Исфаһан, Гыйрак вә Шам һәм, ниһаять, Истанбулда чыккан дәфтәр һәм блокнотлар да очрый. Дәфтәрләрнең гомуми күләме якынча 1260 сәхифә тәшкил итә. Бу дәфтәрләргә карап, галим кылган сәфәрләрнең географиясен, ул йөргән юлларны, зыярәт иткән илләрне, байтак кына шәһәр-калаларны, авылларны барлап чыгып, күзаллап була.

Кулъязмаларның эчтәлегенә килгәндә, ул гаять чуар вә күпкырлы. Биредә дини гыйлем вә дөньяви фәннәрнең төрле

өлкәләренә караган бихисап мәгълүмат-хәбәрләр дә, галимнең уйланулары да, тирән рухи кичерешләре, кайгы-хәсрәтләре дә чагылыш тапкан. Куен дәфтәрләрендә дини мәсьәләләр, мәсәлән, мөтга никяхы[1] турында уйланулар, төрле сүзләрнең килеп чыгышына кагылышлы мәгълүмат, тарихи язмалар, язма чыганакларны өйрәнүгә караган хәбәрләр, география, астрономия һәм ел исәбе турындагы текстлар, сәфәр-сәяхәт кылганда күргәннәрен чагылдырган кыска гына күзәтүләр, теге яки бу шәһәр вә авылларның көндәлек тормышын тасвирлаган парчалар, фәлсәфи уйланулар, төрле шәхесләр белән очрашу-аралашулар, ислам дөньясының сәяси-иҗтимагый вазгыяте турындагы фикерләр һәм башка күптөрле язмалар бар. Кайбер дәфтәрләрдә галимнең фәнни эшчәнлеген чагылдырган язмалар да очрый. Андыйлардан, мәсәлән, Муса әфәндена чит ил китапханәләрнең берсендә язып алган китаплар исемлеге һәм андагы аерым китапларга карата кыскача тасвирламаларны атап була. Дәфтәрләрнең кайберләрендә Муса әфәнденең гарәп яки татар телендә язылган гыйльми әсәрләре теркәлеп калган. Андыйлар арасында гаилә темасына кагылышлы күләмле бер мәкаләсе игътибарны җәлеп итте. Сүз дәфтәрләрнең берсендә урын алган һәм «Гаиләдә хатын» дип аталган 22 битлек әсәр турында бара. Әлеге әсәрнең Муса Бигиевнең «Коръән кәрим айәт кәримәләре нурлары хозурында хатын» исемле китабына кермәгән мөстәкыйль хезмәте булуы ихтимал. Бер дәфтәрдә Зәки Вәлиди Тоган белән очрашканда аның Төркестандагы хәлләр турында сөйләгән хатирәләре теркәлгән.

Моннан тыш, кайбер дәфтәрләр Муса Бигиевнең үзе өчен күчереп яки күчертеп яздырган әсәрләрдән гыйбарәт. Болардан аңлашылганча, Муса әфәнде теге яки бу фәнни текстларны үзе өчен бик әһәмиятле вә кирәкле дип санаган һәм аларны кул астында тоту өчен күчермә нөсхәләрен ясый торган булган. Мисал өчен, П.Ф. Тома исемле авторның «*Фәлсәфә*

[1] мөтга никяхы – ислам фикъһысында карала торган бәхәсле бер мәсьәлә. Бу төшенчәне кайчак «вакытлы никях» буларак аңлыйлар, әмма болай итеп кабул итү аның асылына туры килми.

*дәресләре*» исемле хезмәтенең кулдан күчерелгән нөсхәсе шундыйлардан. Димәк, Муса әфәнде, ислам диненә кагылышлы темалар белән генә чикләнмичә, гомере буе Көнбатыш фәне белән, аерым алганда ориенталистика белән дә кызыксынып, танышып, өйрәнеп торган.

Гомумән, Муса әфәнденең шәхси язмаларын уку дәвамында ул яшәгән дәвернең тере сулышын тоеп, сизеп була.

Муса Бигиевнең язма мирасының куен дәфтәрләрендә сакланган өлешен өйрәнү эше әле башланып кына килә. Алга таба, иншаллаһ, олугъ галимебезнең кыйммәтле мәгълүматка ия бу куен дәфтәрләре турында җентекле тасвирлама языла, алардагы материалларның хәрефләтә күчермәсе булдырылыр, алар хәзерге татар һәм урыс телләренә тәрҗемә ителер. Бу планнар тормышка ашса, Муса әфәнденең куен дәфтәрләренә багышланган, аларның эчтәлеген тулаем чагылдырган һәм үз эченә дәфтәрләрнең һәр битенең фотосурәтен алган махсус бер тасвирлама та дөнья күрер дип ышанып калам.

Биредә Муса әфәнденең көндәлегеннән аның иң самими хисләрен, иң ихлас теләк һәм өметләрен чагылдырган бер парчаны китерү дөрес булыр. Бу өзек галимнең Кәгъбә мәчетенә керүе турындагы хатирәләрен бәян итә:

«***Кәгъбә.*** *Мөхәррам йидедә чәһаршанбә көн ләйләтел-хамисдә*[1] *бәгъдәл-гышаъ*[2] *әл-Маҗид әл-Көрди угылы килде. Сәгать гарәбийә*[3] *такрибән дүрт иде. «Кәгъбә ачулур, буш улур, кидәек*[4]*», – диде. Тәһарәт алдым, шадлануб хазирләндем. Вардым. Халык вар.*

***Кәгъбәйә дөхүлем.*** *Ләкин зәхмәт*[5] *юк. Сәламлә ашдым*[6]. *Дахил улдым*[7]. *Габдуллаһ Шәйба, – кара гарәб, мифтах сахи-*

[1] ләйләтел-хамис – чәршәмбе көннең киче, ягъни, ислам гадәтенчә чәршәмбе көн башланган вакыт. Ислам динендә атнаның һәр яңа көне кояш баеганнан соң башлана.

[2] бәгъдәл-гышаъ – ястү намазыннан соң.

[3] сәгать гарәбийә – Гарәбстанның җирле вакыты буенча сәгате.

[4] кидәек – барыйк.

[5] зәхмәт – кыенлык.

[6] сәламлә ашдым – сәлам белән [баскычы буйлап өскә] мендем.

[7] дахил улдым – кердем.

*бы*[1]*,– капуда*[2] *хазир иде*[3]*. Дүрт рөкендә*[4] *ике рәкәгать намаз кылдым. Дустлар, карендәшләр, балалар, гаъилә хакында, һәммә хакында догалар әйтдем, Коръән догалары да тәмамыйлә лисаныма*[5] *җәри улды*[6]*. Иң мөһим догам: «Йа Рабб, динеңне шәригатеңне бәнем әлемдә ихъйа ит*[7]*, шәригатеңи тәдвин идәйем*[8]*, шәригатеңи бәләдемдә нәшер идәйем*[9]*»,– догасы иде. Хәрәмдә икән*[10] *һәр вакыт лисаныма җәри улмыш дога шу догам иде. Калебемә, лисанга һәр вакыт шу дога илка кылынды*[11]*, иншәъ Аллаһ, вакыйг улаҗак*[12] *бер илһамдыр. Иншәъ Аллаһ»*[13].

1927 елда кылган хаҗдан соң берничә ел үткәч, бер мәктүбендә Муса әфәнде хаҗ сәфәренә кагылышлы хатирәләре белән уртаклашкан: «*1927 елның зөлхиҗҗә ае иде. Иртән сәгать 7 тирәсендә ялгызым Җәбәл ән-Нурны*[14] *зиярәт иттем. Зиярәтемнең максаты анда бер төн вә бер көн игътикяф иде. Тауга менеп башына ирештем. Тау башында кеше кулы калдырган эз-фәлан юк иде. Ләкин Нөбүввәт-е Мөхәммәдия мәктәбе, мөкатдәс Гар, бөтен газаматы белән, бөтен*

---

[1] мифтах сахибы – ачкыч хуҗасы (Мөхәммәт пәйгамбәрнең сөннәте буларак Кәгъбә ачкычлары Шәйба (бану шәйба) нәселеннән булган кара тәнле гарәпләрдә (хәрәм агаларында) саклана).

[2] капуда – ишектә.

[3] хазир иде – тора иде.

[4] рөкен – почмак.

[5] лисаныма – телемә.

[6] җәри улды – агылды.

[7] бәнем әлемдә ихъйа ит – минем кулымда терелт.

[8] тәдвин идәйем – тәртипкә китереп төзимче.

[9] бәләдемдә нәшер идәйем – илемдә (ватанымда) таратыймчы.

[10] Хәрәмдә икән – Изге бинада (мәчеттә, храмда) булган чакта.

[11] илка кылынды – куеды, салынды.

[12] вакыйг улаҗак – тормышка (чынбарлыкка) ашачак.

[13] А5924 (Муса Җаруллаһның куен дәфтәре). Milli Kütüphane. Ankara. Б. 16–17. Хәзерге татар теленә тәрҗемәсе югарыда күрсәтелгән кушымтада китерелә.

[14] Җәбәл ән-Нур (Нур тавы) – Мөхәммәт пәйгамбәр (ﷺ) күп вакытын шул тау башындагы бер куышта (гарда) үткәрергә яраткан тауның исеме.

*рәхәтлек белән, бөтен тынлыгы белән тәмамән әүвәлге хәлендә иде. Гар шул хәлендә тора иде. Иманлы калебемә бөек бер тынлык, эшлекле гәүдәмә куәтле бер ялгызлык килде. Пәйгамбәр әфәндебезнең Хөҗрә-и илаһиясендә Аллаһ җәллә җәлалүһу хәзрәтләренең илчесенең хозурларында Аның кунагы буларак 50 дакыйка кадәр тордым. Бик зур, гадәттән тыш тирән тәэссүрләр эчендә газаматлы бер тынлык, татлы бер тынычлык эчендә 50 дакыйкка кадәр бер заман бу мәдрәсә илаһиядә утырдым. Җанлы хыялымда хәят-е нәбәвия панорамасы үтә торды, калебемдә өметләрем, нәфесемдә догаларым дулкынланып торды. Хөҗрә илаһиядән чыгар идем. Бөтен якларга карар идем. Тәуратта Җәбәл әл-Фәран исеме белән искә алынган кечкенә тауларны тамаша итәр идем. Болар гаскәл бүлекләре, намаз җәмәгатьләре кебек сафлар сисլсиләләре иде. Миңа күрә кодсиятле бер манзара иде. Карый-карый моңа һич туя алмый идем. Соңыннан чыктым. Акрын гына хәрәкәт иттем. Тауның итәгенә төштем. Мәйдан кебек тигез бер җирдә бераз ял итү теләге белән утырдым. Сәййидел-вөҗүд, Шаригъ хәким пәйгамбәр (галәйһис-саләт вәс-сәлам) хәзрәтләре Җәбраил (галәйһис-сәлам) хәзрәтләре белән бергә беренче намазны, мөхтәмәлән, биредә үтәгәндер дидем. Анда 15 дакыйка кадәр калдым».*

Хаҗ сәфәреннән кайтышлый Муса әфәнде июль аенда берничә көнен Мәдинә-и Мөнәввәрәдә үткәрә, аннары Сүрия аркылы уза, андагы хәлләр белән таныша. Ниһаять, Төркиягә юл тота. Аның юлъязмаларыннан аңлашылганча, Төркиягә ул 8 августта килеп төшә һәм 1927 елның 25 декабрендә «Ильич» пароходы белән туган иленә кайтып китә. 1926 елда Истанбулда бастырыр өчен калдырган «*Шәригать исламийә назарында мөскират мәсьәләләре*»[1] дә китап булып нәшер ителгән була инде. «*Ислам милләтләренә*»дән соң бу китап Муса әфәнденең чит илдә чыккан икенче китабы була.

[1] Муса Җаруллаһ. Шәригать исламийә назарында мөскират мәсьәләләре. Мәхмәд бәк матбагасы, 1927. 48 б.

## Упкын өстендә

1929 елның февраль аенда ВКП(б) Үзәк Комитеты махсус карар кабул итеп, илдәге дини оешмалар белән актив, хәтта агрессив көрәш дәверенә атлый. Дини оешмалар контрреволюция учаклары буларак эзәрлекләнә башлыйлар, бетереләләр, Коръән ясакланган (тыелган) китаплар исемлегенә кертелә[1]. Мөселман дин әһелләрен киң колачлап кулга алулар, репрессияләргә дучар итүләр башлана. Әмма Советлар Берлегендә яшәгән дәвердә, башы өстендә болытлар никадәр куерса да, Муса әфәнде кул кушырып утырмаган. Мәсәлән, 1929 елның ноябрь аенда Финляндиядәге дусты Зиннәтулла Әхсән Бүрегә язган бер хатында Муса әфәнде: «*Ислам голүменә, Коръән голүменә, гарәп әдәбиятына рагбәтле булган таләбәләр өчен әдәби мәдрәсә ачу юлында тырышлык куям*» дип язган. Муса әфәнденең Әхсән Бүрегә мәктүбенең күләменә караганда, бу ике кеше бик якын фикердәш дуслар булганнар. Муса әфәнденең дуслары даирәсенә кергән һәркем үзенә күрә махсус бер игътибарга лаек, чөнки остазның алар белән аралашуы, бергә эшләгән эшләре, фикер алышулары булсын – болар барысы да Муса әфәнденең шәхсиятен дә, аның кичерешләрен, карашларын, уй-фикерләрен яхшырак, биографиясендә булган вакыйгаларны, аерым детальләрне аңларга мөмкинлек бирә. Шуңа кушымтада Әхсән Бүрегә атап язылган бу мәктүпнең тәрҗемәсен китердек[2].

Шулай итеп, гомумән дингә һәм, аерым алганда, дини мәгариф системасына дәүләт тарафыннан корыткыч һөҗүм башлануына карамастан, Муса әфәнде халыкка дини тәгълиматны ирештереп тору юлларын эзләгән һәм, тиешле чаралар күреп, аларны тормышка ашырырга тырышкан. Бу дәвердә Муса әфәнде татар мәдәни тормышында күзәтелгән вакыйгалар белән дә кызыксынып торган. Әмма коммунистик пропаганда белән исәрләнгән яңа татар интеллигенциясе вәкилләре Му-

[1] Мухетдинов Д. Российское мусульманство: в поисках политической субъектности. 2021. С. 101.

[2] Карагыз: III Бүлек. 19: Муса әфәнденең Зиннәт Бүрегә язган хаты.

са әфәндегә карата яман мөнәсәбәттә булалар. Олуг галимгә карата мөнәсәбәтнең никадәр үзгәрүенең бер мисалы Кави Нәҗминең[1] «Кызыл Татарстан» исемле гәзиттә басылган мәкаләсендә сурәтләнә: 1929 елда СССР республикаларын иҗади сәфәр белән айкап кайткан татар язучылары һәм мәдәният хезмәткәрләре Мәскәүдә отчет җыелышларын үткәрәләр. Бу чара Муса әфәндproperенең дә игътибарын җәлеп иткәнгә күрә, җыелышка ул да килә. Әмма аны күреп алгач, яңа татар «зыялылары» аяклары белән идән кагып, сызгырып-кычкырып олуг галимне залдан чыгып китәргә мәҗбүр итәләр.

[1] Кави Нәҗми (Һибәтулла углы Кави Нәҗметдинов; 1901–1957) – танылган совет татар язучысы һәм җәмәгать эшлеклесе, СССР Язучылар берлеге әгъзасы.

# Дүртенче фасыл
# Горбәттә үткәргән еллары.

## Илдән качып китүе. Шәркый Төркестан

Мондый шартларда алга таба да илдә яшәү мөмкинлеге, әлбәттә, тарая гына түгел, тәмам бетә. Шул ук вакытта илдән гаиләсе белән рәсми төстә эмиграциягә китәргә рөхсәт соравы нәтиҗәле булмый. Шуңа күрә Муса әфәнде горбәтлеккә качып китәргә карар кыла һәм 1930 елның ахырына таба, якыннарына Финляндиягә таба юл тотачагы турында хәбәр биреп[1], чынлыкта бөтенләй кире тарафка – Төркестанга юнәлә. Бирегә ул ноябрь аенда килеп җитә һәм, НКВД агентлары аны Финляндия чикләрендә көтеп торган мәлдә, Кыргызстандагы ышанычлы дусларының ярдәме белән, яшерен рәвештә, Советлар Берлеге-Кытай чиген кичеп, Шәркый Төркестанга качып китеп, андагы Шимханә шәһәренә барып чыга. Муса әфәнде өчен бу сәфәр җилкәсенә биштәр асып юлга чыгу булмый – галимнең янында китаплары, кульъязмалары тутырылган кимендә алты сандык багаж була. Шуңа күрә Андижаннан Габдерахман Насретдин белән Сабыр Ахунның һәм Ош кешесе Хәлим Ахунның Муса әфәндегә күрсәткән ярдәмнәре ул китапханә вә архивның сакланып калуында хәлиткеч роль уйный. Шулай итеп, Муса әфәнде биш Франция кадәр булган Шәркый Төркестанга, хәзерге вакытта Кытайның Синҗән-Уйгыр автономияле районы буларак мәгълүм төбәккә барып керә. Ә Муса әфәндегә чик аша узарга ярдәм иткән кешеләр соңыннан кулга алыналар һәм Совет власте тарафыннан үлем җәзасына хөкем ителәләр. Бу игелекле фидакяр затларның исемнәре 1929–1932 елларда Ташкенттагы Чин консуллыгы тәрҗемәчесе, чыгышы белән Шәркый Төр-

[1] Бу факт Уралгирәй язган хатирәләрдән мәгълүм (Uralgiray. Önsöz, s. XVII).

кестаннан булган Гайсә Йосыф Альптекин исемле бер уйгыр кешесе аркылы билгеле.

Муса әфәнде дус-ишләре күп булган уйгырлар иленә кергәндә аның башкаласы Кәшгарда урнашып, моннан гаиләсенә бер хәбәр ирештерү әмәлен дә таба, һәммәсеннән дә гафу үтенә[1]. Кәшгарда Муса әфәнде мәдрәсә ачып, шунда төпләнеп калырга ниятләгән була. Биредә ул «***Сарфу әл-Куръәни әл-кәрими***» исемле әсәр дә язып өлгерә яки башланган кульязмасын тәмамлый[2]. Бу факт Муса әфәнденең качып китәчәге турында аның хәтта иң якын кешеләренең дә белмәгән булуларын дәлилли.

Остазыбыз Шәркый Төркестан җиренә аяк баскан көннәрдә андагы сәяси-иҗтимагый вазгыять гаять чуар, катлаулы һәм шартлар дәрәҗәдә киеренке була. Шәркый Төркестан 1911 елдан бирле Кытай хакимияте астында була. Шулай да үзләрен кытайлылар кулы астында яшәүдән азат итәргә теләгән уйгырлар еллар дәвамында оккупацион режимга каршы күпсанлы коралды күтәрелешләр оештыралар һәм беренче мәртәбә 1933, икенче мәртәбә 1944 елларда Шәркый Төркестанның ике өлешендә бәйсез Көнчыгыш-Төркестан Республикасы (Шәркый Төркестанның Төрек Ислам Җөмһүрияте) төзүгә ирешәләр. Шуңа күрә уйгырларны бугазлап тоткан Кытай идарәсе җирле мөселманнар күзендә абруй вә дәрәҗәсе гаять олы булган Муса әфәндене илдән китәргә мәҗбүр итә. Кытай хакимияте Муса Бигиевнең уйгыр халкын дини идеяләргә таянулы милли-азатлык көрәшенә күтәрә алуыннан курыккан дип фараз кылырга бик мөмкин. Шулай итеп, Муса әфәндене, Кытай администрациясе билгеләгән махсус коралды каравыл күзәтүе астында, Әфганстан чигенә таба озаталар. Муса Бигиевнең үзе язуынча, Әфганстанга «балта

---

[1] Кәшгардан җибәрелгән хәбәр турында 1986 елда Муса әфәнденең кызлары Мәрьям ханым (Уфа) белән Фатыйма ханым (Ленинград) белән танышып аралашу бәхетенә ия булган М. Рәхимкулова яза. Карагыз: Рахимкулова М.Ф. Медресе «Хусаиния» в Оренбурге. Оренбург: «Яңа Вакыт», 1997. С. 42.

[2] Китап 1944 елда Һиндестанда басылып чыга.

тимәгән урманнар аша дүрт ай дәвамында» бара. Бу айларның кышка туры килгән айлар булуын истә тотканда, сәфәрнең никадәр авыр һәм куркыныч булуын чамалап була. Муса әфәнде бу турыда мондый сүзләр язып калдырган: «*Кабулга барып җиткәнче дүрт айдан атка атланып сәяхәт иттем. Юлда табигатьнең искиткеч манзаралары белән каршылашканда, милләтләрнең күп гаҗәеп хәлләрен күргәндә юл газапларын азмы-күпме онытып тора идем. Бу вакытта кичергән иң зур кыенлык мине якыннан күзәткән, үткәрергә теләгән эзләнүләремне башкарырга, теләгән җиремдә туктарга мөмкинлек бирмәгән сакчыларның каравылы астында булуым иде*».

## Әфганстанда кырык көн. Мисыр һәм Бөтендөнья мөселман конгрессында.

1931 елның март аенда Әфганстан падишаһы Надир-Шаһ[1] Муса Бигиевне олылап каршы ала, хөрмәтле галимнең Кабул шәһәрен бик яратканын белеп, биредә калырга, үзе теләгәнчә яңа интизамлы мәдрәсә ачып төпләнергә тәкъдим итә. Әмма Муса әфәнденең ниятләре башка була. Мәртәбәле кунагының үтенечен үтәп, Надиршаһ аңа чит ил паспорты ясата. Бу паспорт белән Муса әфәнде өчен бөтен юллар ачыла. Алга таба гомеренең азагына кадәр диярлек ул Әфганстан ватандашы (гражданы) буларак сәфәр итә.

Кабул турында Муса әфәнде мондый сүзләр язып калдырган: «*Кабулда торып алдым. Ул җир йөзендәге җәннәттер, илләрнең иң яхшысы, шәһәрләрнең иң гүзәле, Шәрыкта иң яхшы башкала. Кырык көн дәвамында аның игелекле хөкүмәтенен кунагы буларак көттем. Аңарда дүрт урта мәдрәсә бар, алар низам вә тәртибе белән иң камил мәдрәсәләрдер. Сабак дүрт телдә укытыла: инглиз, алман, фиранс, фарсы. Һәр мәдрәсәдә үз укыту теле, һәм аны тәмамлап чыгучы телне камил сурәттә белә – аңарда яза да, укый да. Күргәннәремнән*

[1] Мөхәммәд Надир-Шаһ (1883–1933) – Әфганстанның 1929–1933 елларда хакимлек иткән 4нче падишаһы.

*белдем ки, Әфганстан дәүләте бүген ислам дәүләтләренең иң куәтлесе һәм мәдәниятлесе…*

*Кырык көн көтеп үткәрдем, соңыннан Аллаһ җәллә җәлалүһу бөек падишаһ җәнабләре хәзрәт Надир шаһның ишарә итүе белән алдымда сәфәр капкаларын ачып җибәрде*»[1].

Кабулда кунак булганнан соң, Муса әфәнде башта Һиндестанга китеп бара, аннан Мисырга барып, анда «*Төркия Бөек Милләт Мәҗлесенә мөрәҗәгать*»ен бастыра. Мисырдан 1931 елның ноябрь аенда Муса әфәнде Финляндиягә сугыла да, бераздан Гаяз Исхакыйның чакыруы белән Берлинга китә. Биредә алар Әл-Кодестә (Иерусалим) үткәреләчәк Бөтендөнья мөселман конгрессына бару турында килешәләр һәм юлга чыгалар. Әл-Кодестә җыелган конгресс декабрь аеның 6–17 декабрендә эшли. Ул әл-Кодеснең Бөек мөфтие Мөхәммәд хаҗи Әмин Әл-Хөсәйни (1897–1974), тунислы галим һәм сәясәтче Габделгазиз әс-Сәгалиби (1876–1944) һәм Һиндестан мөселманнарының атаклы сәяси җитәкчесе хилафәт активисты Мәүлана Шәүкәт Гали (1873–1938) кебек күренекле шәхесләрнең инициативасы белән үткәрелә. Бу чарада ислам дөньясының Сүрия, Лүбнән, Урдун, Йәмән, Либия, Җәзаир, Тунис, Һиндестан, Мисыр, Согуд Гарәбстаны, Сәрандиб (Сәйлүн), Индонезия, Идел-Урал, Төркестан, Кырым, Шәркый Төркестан һәм Финляндия, Кафказ, Югославия, Иран, Гыйрак, Филистыйн, Фәс (Марокко), Арнавутлык (Албания), Нигерия кебек, җәмгысы 22 илдән җыелган 145 делегат – дин галимнәре, дәүләт эшлеклеләре, эшмәкәрләр, төрле сәяси фирка җитәкчеләре, галимнәр, журналистлар катнаша.

Муса Җаруллаһ конгресста Шәркый Төркестан һәм Финляндия мөселманнарының делегаты буларак катнаша. Корылтай эшен башлаганда ук төрле комиссияләргә әгъзалар тәгаенләнә. Муса әфәнде Тәкъдимнәр комиссиясенә сайлана. Муса әфәнденең корылтайда беренче чыгышы 11 декабрьдә,

[1] Муса Җаруллаһ. Әл-Вәшигату фи нәкъди гакаъиди әш-шигати. Каһирә: Матбагату әл-Киляни, 1982. Б. 22–23.

җомга көн иртән үткәрелгән 7 нче сессия, ягъни съездның бишенче көнендә яңгыратылырга тиеш була, чөнки ул конгресс рәисеннән нәкъ менә бу утырышта чыгыш ясар өчен рөхсәт сорый. Әмма иртәнге утырышта барлык делегатларның нибары өчтән бере генә катнашканга күрә, аның чыгышы җомга намазыннан соң үткәреләчәк сессиягә күчерелә. Болай ителүне Муса әфәнде үзе тели – ул әйтәсе сүзе үтә дә әһәмиятле булганга күрә, җитди фикер алышу үткәрергә җыенган була. Өстәвенә ул съездны алып баручыларга аңа кадәр башка һичкем ясамаган кадәр зур күләмдә акчалата багыш (взнос) ясаячагын белдерә. Шулай итеп, җомга намазыннан соңгы утырышта Муса әфәнде минбәргә дәгъвәт ителә.

Муса әфәнде үзенең гарәп телендә сөйләнгән нотыгында болай ди: «*Әлегә кадәр һаман да башкарылмаган бер вазифам һәм җилкәмдә үтәлмәгән бер әманәтем бар. Мин зур бер милләттән килдем. Сәламнәрем белән һәм мине сезгә юллаган миллионнарча Чин Төркестаны һәм Финляндия мөселманнарының сәламнәре белән сезне сәламлим. Алар: берәүләре зәкят түләгән байлар, берәүләре фәкыйрь буларак – ике сыйныфтыр. Бу ике сыйныфның бәрәкәте белән өммәт яшәр, сәнәгать һәм сәүдәсе белән баер. Аларда урлашуны белмиләр; аларның телләре ялган сөйләмәс һәм алар арасында сәрхуш һәм фәхишә табылмас; алар хаммамнарга качып кына керәләр.*

لنا صاحب لا ينبغى أن نخونه * وأنت لأخرى فارغ وحليل[1]

*Безнең хәлебез тимер юл хәле кебек. Безнең яңа бер карарга ихтыяҗыбыз юк. Киресенчә, безнең бу юлда махсус буларак электән алынган карарларны гамәлгә ашыруга эзлекле сурәттә хәрәкәт итәчәк кешеләргә ихтыяҗыбыз бар. Мин кайбер делегацияләрнең Көнбатыштагыларның мәдәнияттә бездән өстен булуларына кагылышлы әйткән сүзләренә кушылмыйм. Көнбатыш бездән бары тик матди мәдәнияттә*

---

[1] Безнең үзенә хыянәт итәргә ярамаган бер аркадашыбыз бар / Син исә башка беренә юнәлеп аны дус итәсең. (Өмәвиләр дәвере шагыйре Ләйлә бинт Габдуллаһ иҗатыннан).

*өстен чыкты. Без дә аларга нисбәтән рухи мәдәнияттә өстенбез*»[1].

Муса әфәнденең чыгышы озакка киткәч, Гауни Бәй Габделһади[2] чыгышка бәйле фикер алышуны башка утырышка күчерергә тәкъдим ясый. Муса әфәнде «*(шимбә көн) иртән беренче утырышта миңа сүз бирсәгез, зарар юктыр*» дигәннән соң, минбәр башка докладчыга бирелә. Әмма бу чыгыш Муса әфәнденең корылтайда әйткән беренче һәм соңгы сүзе була, чөнки яңгыраган чыгышларны теркәп барган чыганакларда аның нотыгы буенча фикер алышулар үткәрелүен яки аның башка чыгышлары булганлыгын раслаган язмалар хәзергә табылмаган. Аңа кагылышлы соңгы хәбәргә күрә, декабрьнең 28-ендә Муса әфәнде Хайфа шәһәрендә яшәгән Габдулла Тимер[3] исемле кешедә кунак була. Бу хәбәр аның Кодестән китеп барган көнен чамаларга мөмкинлек бирә. Әл-Кодестә Муса әфәнденең Бөек мөфти Мөхәммәд хаҗи Әмин Әл-Хөсәйни белән танышкан булуын дә әйтеп узарга кирәк.

Сүз уңаеннан, корылтайда Идел-Урал комитеты вәкиле буларак Гаяз Исхакыйның да чыгыш ясавын искә алырга кирәк. Үзенең гарәп телендә яңгыратылган ялкынлы нотыгы белән ул конгресс тарихына да, милли-азатлык көрәше тарихына да кереп кала.

Әлеге конгресста хилафәт мәсьәләсе каралса да, ул хәл ителми һәм, Госманлы хилафәте юкка чыгарылу сәбәпле, ислам милләтләренең планета кимәлендә гаять зәгыйфьләнгән булуларын истә тотканда, хәл ителә алмый да. Шулай да бу конгресста кабул ителгән карарлар киләчәктә, ягъни без-

[1] Төрек теленнән тәрҗемә. Чыганак: Koca, Ferhat. «Musa Carullah Bigiyef ve İslam Kongreleri (1926–1931)», Hitit İlahiyat Dergisi, (Haziran/June 2022) 21/1, 33–80

[2] Гауни бәй Габделһади (1882–1970) – сәясәт эшлеклесе, Гарәп бәйсезлек партиясен (Җәмгыятел-гарәбийәтел-фәтати) оештыручыларның берсе, дәүләт эшлеклесе, 1951–1956 елларда Урдунның Каһирәдәге Бөек илчесе, 1956 елдан Урдун тышкы эшләр министры.

[3] Габдулла Тимер Казаннан килеп, Хайфада төпләнеп калган бер галим буларак билгеле.

нең көннәрдә дөнья мөселманнарын берләштереп, аларның авазын җиһанга ишеттереп торган «Ислам конференциясе оешмасы» (Организация Исламская конференция; ОИК) һәм «Ислам хезмәттәшлеге оешмасы» (Организация исламского сотрудничества; ОИС) кебек халыкара оешмаларның беренче нигез ташларын тәшкил итәләр.

## Таһир Хәлиминең хатирәләре

Кодестән соң Муса әфәнде Әнкара белән Истанбулга барып чыга. Биредә ул Берлинда оештырылачак нәшрият вәкиле буларак эшләр башкара. Шул көннәрдә аның белән Таһир Хәлими[1] исемле кеше таныша. Ул мондый хатирәләр калдырган: «*1930 елларда «Нәкъли гыйлемнәр тарихы» исемле китабымны бастыру өчен «Асары гыйльмия көтебханәсе»н ачкан газиз дустым Әшрәф Әдип*[2] *бәйнең киңәшләрен алганда ул көннәрдә Кодестән Әнкарага һәм аннан Истанбулга кичкән мәрхүм Муса Җаруллаһның Алманиядә Шәрык ислам әсәрләрен нәшер иткән җәмгыятьнең вәкиле буларак биредә*

[1] Таһир Хәлими (Tahir Halimî Balcıoğlu; 1893–1952) – дәүләт эшлеклесе, фәлсәфәче, тарихчы галим. «Әл-Әзһәр» университетын тәмамлаган, соңыннан туган шәһәре Әдрәмиттә дәүләт хезмәтендә була, бер ара Әнкарада Милли китапханәдә эшли. Кайбер хезмәтләре: «Tarih-i Medeniyette Kütüphaneler» (1931) («Мәдәният тарихында китапханәләр»); «Tarihte Edremit Şehri» (1937) («Тарихта Әдрәмит шәһәре»); «Türk Tarihinde Mezhep Cereyanları» (1940) («Төрек тарихында мәзһәб агымнары»). Моннан тыш, ислам фикере һәм фәлсәфәсе тарихына, шул исәптән аерым дин галимнәренә, тәсаввыфка кагылышлы күпсанлы хезмәтләр һәм мәкаләләр авторы. Аның «Mezâmîr-i Felsefeden İnsaniyete Veche Veren Büyük Ruhlar» (1927) исемле әсәре кулъязма рәвешендә үзе тарафыннан Милли китапханәгә тапшырылып, вафатыннан соң, китап итеп чыгарыла. Әсәрнең нигезендә авторның күргән дүрт төше ятуы әлеге китапны жанры ягыннан да, эчтәлеге ягыннан да гаять кызыклы бер әсәр булуына ишарә итә.

[2] Әшрәф Әдип (Әшрәф Әдип Ферган; 1882–1971) – төрек журналисты, «Sırat-ı Müstakim» исеме белән башланып, соңыннан «Sebilürreşad» исеме белән чыккан ислам журналының баш мөхәррире һәм нашире.

*булуын һәм аның белән бу эш буенча күрешү үткәреләчәге турында белдем. Инде никадәр еллар дәвамында калебемдә бу кешегә карата яшәгән иң югары бер олылау һәм ярату аркасында бу бөек ислам галимен күрү форсатына юлыгуым сәбәпле аеруча бер дулкынлану кичердем.*

*Ике көн үткәч шул ук көтепханәдә кулларын үпкәндә дулкынлануымнан хәтта тәнемнең калтыравын тойдым. Ул гыйлем һәм фазыйләт адәменең хозурында тәмам эредем. Хәятемдә төрле өлкәләрдә шан вә шөһрәт казанган берничә шәхес белән кара-каршы килеп танышканым булды. Фәкать болар арасында Муса Җаруллаһ кимәлендә тулы вә мөкәммәл бер кешене очратуым бик сирәктер. Арабызда егерме ел якын дәвам иткән дуслык дәверендә иң тирән ислам гыйлемнәренә караган теләсә нинди мәсьәләләрдә аның кадәр хөр вә мөстәкыйль фикер йөрткән ислам мөтәфәккирен күрмәдем. Башына берничә китапханә сыйдырган, шул ук дәрәҗәдә ислам мәүзугында белдекле һәм мәгълүмат иясе булган замандаш дин бөекләре һәм мөтәфәккирләре арасында бик аздыр. Зәррә кадәр тәгассыбы*[1] *юк иде, игътикадына күрә ислам хокукының нигезләре өстенә яңа иҗтиһад корылуына катгый зарурәт барлыгын, хөкем итүгә чыганак булган нигезләр турысында һәм бөтен тәшригый мәсьәләләр*[2] *хакында башыннан ахырына кадәр тикшеренүләр үткәрергә кирәклеге турында сөйләштек. Бу фикерләрен күпсанлы әсәрләрендә хәлебезгә тиешле бер дәва буларак алга сөргән иде. Банк һәм фаъиз*[3] *хакында һәм бүгенге икътисади агымнар белән ислами хөкемнәр арасында каршылыкларга кагылышлы мөһим уйларын тыңлаган идем. Хәтта бу хосуста Багдад голәмәсе белән мөзәкарәләрдә катнашуы турында тыңлаган идем. Җиде гасыр элек ислам дөньясын үзенең даһилыгы һәм кодрәте белән хәйран калдырган Ибне Тәймийя турында мөһим бер*

[1] тәгассыб – үзгәлекне кабул итә алмау; үзгә булган нәрсәгә карата нәфрәт тою; фанатиклык.

[2] тәшригый мәсьәләләр – шәригать кануннарын булдыруга караган мәсьәләләр.

[3] фаъиз – процент.

*әсәр язган мәшһүр хәдис галимнәреннән Ибне Һадый әйтә ки: «Ибне Тәймийя сөйли башлаган вакытта ике күзе дә, әйтерсең, сөйләшеп торучы ике тел иде. Һәртөрле мәүзугта ачыклама биргәндә бер елганың ничек туктаусыз агышы бар исә, ул да шул темада шулай иде. Әйтерсең ки, гомер буе тик шул темада тирәнәю өчен яшәгән». Мин дә мәрхүм остаз белән очрашкан мәлләрдә күзләрендәге камаштыручы нур балкышын күреп, Ибне Һадыйның Ибне Тәймийя хакындагы бу сүзләрен Галләмә Җаруллаһка тәмам туры килүен зиһенемдә күрәм»*[1].

Таһир Хәлимигә килгәндә, ул Муса әфәнде турында яшь чагыннан ук ишетеп белгән: әле 1912–1915 елларда «Әл-Әзһәр»дә укыган елларда, татар шәкертләренең кулларында йөрткән китапларын күреп, аның турындагы сүзләрне ишетеп торган һәм бу кешенең никадәр олуг шәхес, галим булуын аңлап, гомере буе аның белән танышырга өметләнеп яшәгән. Өмете тормышка ашып, Муса әфәнде белән шәхсән танышып, аралашып, дуслашып яшәгән кешенең хатирәләре, әлбәттә, укучыларыбызга җиткерелергә тиеш, чөнки мондый шаһитләр Муса Бигиевнең нинди кеше булуын яхшырак аңлау өчен юл ачалар.

Сүз уңаеннан, биредә – Неслихан ханым белән сөйләшеп утырганда аның исенә төшкән бер хатирәсе белән уртаклашасым килә. Неслихан Арул Аксой – Габдерәшит Ибраһим хәзрәтнең Тимур исемле угылының кызы Гөлшәннең кызы, ягъни Ибраһим хәзрәтнең оныгының кызы. Ул Төркиядә яши, адвокат. Кан чакыруы үзенекен итеп, Неслиханны профессиональ эшчәнлеген куеп торып, аның өчен бөтенләй ят булган мәсләккә: татар иҗтимагый фикере тарихына һәм шөһрәтле бабасының тормышын өйрәнү юлына кертеп җибәрә. Тырышлыгы, үзсүзлелеге белән Неслихан бабасы турында диссертация язып, аны уңышлы яклый, шулай итеп галимә дә булып китә. Студент чагында, ягъни 1980 еллар башында Неслихан Истанбулда дәү апасы Фәүзия ханымда яшәгән. Фәүзия ха-

[1] Tahir Harimi Balcıoğlu. Büyük islam âlimi Musa Carullahı nasıl tanıdım. Sebilürreşad. 1949. Cilt: III; Sayı: 65. Sayfa: 237–238.

ным Габдерәшит хәзрәтнең яшьли вафат булган беренче хатыныннан туган олы кызы була. Ул Муса әфәнденең дә якын дусты, фикердәше булып, галимнең Каһирәдә үткән гомеренең соңгы көннәрендә янында булып, аңа кулыннан килгән кадәр ярдәм итеп, терәк булып торган ханым[1].

Бервакыт Неслихан ханымнан:

– Фәүзия апаның Муса Җаруллаһ турында сөйләгәне булдымы? Нәрсә дә булса хәтерлисеңме? – дип сорадым.

Күпмедер вакыт хатирәләрен барлап утырганнан соң, Неслихан:

– Муса әфәнде дәү апамның теленнән төшми иде, ике сүзенең берсе «Муса», иде, гыйбрәтле хәлләр турында сөйләсә дә гел аны искә ала иде. Әмма шул чакларда сөйләгәннәренең эчтәлеге исемдә һич юк. Яшь идем ич, игътибар итмәгәнмен. Хәзерге акылым ул чакта булса иде, һәр сүзен язып барыр идем,– диде дә, тагын бер ара тынып торгач:

– Муса әфәнде турында сөйләгәндә әби апамның йөзе яктырып китә иде,– дип өстәп куйды.

Муса әфәнденең күзләрендә балкыган нур турында аны белгән кешеләрнең хатирәләреннән укып беләм. Җаны-тәне, акылы, күңеле белән, һәр күзәнәгенә кадәр тулысынча Аллаһка бирелеп, аны сөеп, аңа мөкиббән бәндәләрнең генә күзләре шундый буладыр, могаен. Ул нур, бәлки, Муса әфәнде белән аралашкан кешеләрнең күңелләренә үтеп кереп, шунда бер төрдә энҗе бөртеге кебек саклана торган булгандыр? Муса әфәнде белән аралашу бәхетенә ия булган бәхетлеләрнең дә йөзләрен нурландырып, балкытып торгандыр? Фәүзия ханымның хатирәләре шуны раслый түгелме?

### Берлиндагы нәшрияты һәм анда басылырга тиешле китаплары.

Төркиядән Муса әфәнде кире Берлинга кайта һәм нәшрият ачу эшләре белән шөгыльләнүен дәвам итә. Бу дәвердә Финляндиядәге дусты имам Вәли-Әхмәт Хәким хәзрәтлә-

[1] Фәүзия ханым турында тулырак мәгълүмат өчен карагыз: Хайрутдинов А. Г. Общественная деятельность Фаузии Ибрагимовой. Minbar. Islamic Studies. 2022; Т. 15 (№ 2); Б.303–324.

ренә язган хатта Муса әфәнде болай дигән: «*...бу минутта янымда Коръән кәрим бар. шул ук вакытта зур бер хәдис хәзинәсе китабын мөталәгә итәм. Каршыма шундый хәдис килеп чыкты:* (من جاء أجله وهو يطلب العلم ليحيى به الاسلام لم يفضله النبيون الا بدرجة)[1]. *Моңа сөендем. Янымда балаларымның һәм ишемнең хәйалләре[2] беленде, аларны күрдем. Бераз егладым. Күз яшьләрем җәһәннәм утларын да, хәсрәт утларын да сүндерде. Калебем дулкынланып ташыды. «Гойунел-әхбар» исемле дүрт томлык бер китапта бу мизгелдә гаять сәер бер нәрсә укыдым. Хак гадәләткә, гадәләт исә кайчак хакка туры килми. Фикерне кабул иттем. Бу төшенчәне хуш күрдем. Мондый бер аңлатмага юлыгуым гаять яхшы булды. Фикеремдә уяндым. Бу зур бер файдадыр*».

Җавап хатында Вәли-Әхмәт хәзрәтләре остазының «уяндым» дигән сүзенең мәгънәсен сорагач, Муса әфәнде болай дип язган: «*...беләсез, сезгә мәгълүмдер. Бәлки өегездә дә бардыр. Минем «Шәригать әсасләре» атлы бер китабым бар. 16–17нче сәхифәләрендә, [шәригать] хөкемнәре ике төрле була дигән идем. Берсе ибтидаъи [тумыштан хас] хөкемнәр, икенчесе исә вифакыйдыр. Шәригать хөкемнәре, әлбәттә, һәрвакыт хак була. Әхкям ибтидаъия, әлбәттә, һәр заман тугры була. Вифакый хөкемнәр хәлләрнең беренә туры килү зарурияте белән кайчак гаделлек хөкеме белән кара-каршы килергә мөмкин. Моны ачык сурәттә 23 нче сәхифәдә язган идем. Табыгыз һәм укыгыз. «Гойунел-әхбар»ның бер томы 300 сәхифә кадәр зур китаптыр. Төзүчесе Габдуллаһ б. Мөслимдер. Бу зат бөек бер имамдыр. Әһле сөннә вә-л-җәмаганең Җаһизыдыр[3]. Беренче томда бер тапкыр 62 нче сәхифәдә, бер тапкыр 104 нче сәхифәдә шуны әйткән һәм*

[1] исламиятне терелтмәк өчен гыйлем эстәгән хәлендә вафат булган кемсәдән пәйгамбәрләр нибары бер адымга гына өстенрәктер (хәдис).

[2] Хәйал – шәүлә; образ.

[3] Җаһиз (Әбу Госман Гамер ибне Бәхер әл-Кинани әл-Басри; 775–868) – гарәп язучысы, фәкыйһ, гарәп әдәби тәнкыйтенә нигез салучы.

*кабатлаган: «Хак кайчак гаделлеккə, гаделлек кайчак хакка каршы килə ала. Үрнəк буларак – җəза биргəндə җан исəбенə җан үтерү хактыр. Фəкать бер хөр кешене кол урынына үтерү гаделлектер, хак түгел. Өй хатынына дият хактыр, гаделлек түгелдер».*

*Мəзкүр төзүче шулай дигəн. Бу сүз хушыма китте исə дə аны ачыклау рəвешен охшатмадым. Тагын да дөресрəк үрнəклəрен, егерме өч ел элек «Кавагыйд фикъһийə»мдə, 16 ел элек «Шəриать əсаслəре» исемле китабымда тагын да нигезле һəм урынлы бер сурəттə язган идем. «Гойунел-əхбар»нең сүзе мине бераз уярды. Шатландым, сөендем; чөнки минем бəяным тагын да колачлырак, тагын да җыйнактыр. [Җинаять өчен] җəза, гаделлек түгел, бер зарурəттер. (وَجَزَاء سَيِّئَةٍ سَيِّئَةٌ مِّثْلُهَا)[1]ифадə кəримəсенə[2] күрə начар бер зарурəттер.* (وَأَن تَعْفُواْ أَقْرَبُ لِلتَّقْوَى)[3] (وَإِن كَانَ ذُو عُسْرَةٍ فَنَظِرَةٌ إِلَى مَيْسَرَةٍ)[3] *кебек айəт кəримəлəргə күрə хактан вə гаделлектəн тагын да артык бер дəрəҗə гафудыр. Моңа сөендем вə үземне кисəттем. Моннан соң, иншаллаһ, бастырачагым 20–25 данə китабымның бəяннарын янə тугры булыр өмете миңа җан, кыюлык бирде. Менə «уяндым»ның мəгънəсе будыр».*

Бу хатның ахырында искə алынган «*20–25 данə китабым*» гыйбарəсенə аерым игътибар итəргə кирəк. Болар галимнең, хəзерге тел белəн əйткəндə, «редакцион портфелендə» басылырга əзер булып яткан хезмəтлəренə ишарəдер. Аларның исемлеге дə сакланган[4]. Аның төзелешеннəн үк бу хезмəтлəрнең, чыннан да, хəтта исемнəре дə бер калыпка салынган чылбыр-силсилə буларак планлаштырылганлыгы күренə: Муса əфəнде һəр китапның исемендə башлап җибəрəчəк «***Коръəн кəрим айəт кəримəлəренең могъҗиз ифадəлəренə күрə***...»,

[1] «Начарлыкның җəзасы шуңа тиң булган начарлыктыр» (Коръəн, 42:40).

[2] ифадə кəримə – игелекле сүз; игелекле белдерү.

[3] «əгəр (əҗəткə алучы) авыр хəлдə булса, җиңеллек килгəнче көтеп тору» (Коръəн, 2:280).

[4] Муса Җаруллаһ. Коръəн кəрим айəт кəримəлəренең могъҗиз ифадəлəренə күрə Йа́җүҗ. Берлин, 1933. Тышл. 4нче б.

ягъни «Игелекле Коръәннең игелекле айәтләренең могъҗизалы гыйбарәләренә күрә...» дигән гыйбарәне исемлекнең башына чыгарган да, шуннан соң һәр китапның төп темасын белдергән сүзләрне номерлап тезеп киткән. Бастырылырга тиешле булган ул әсәрләрнең исемнәрен түбәндә тулы шәкелдә китердек:

*1) **«Коръән кәрим айәт кәримәләренең могъҗиз ифадәләренә күрә кяъинат һәйәте**»* («Игелекле Коръәннең игелекле айәтләренең могъҗизалы гыйбарәләренә күрә космос төзелеше»)[1];

*2) **«Коръән кәрим айәт кәримәләренең могъҗиз ифадәләренә күрә мәдәният тарихы**»* («Игелекле Коръәннең игелекле айәтләренең могъҗизалы гыйбарәләренә күрә мәдәният тарихы»);

*3) **«Коръән кәрим айәт кәримәләренең могъҗиз ифадәләренә күрә «Гаһыд гатыйк» «Гаһыд җәдид» нәбиләренең китаплары**»* («Игелекле Коръәннең игелекле айәтләренең могъҗизалы гыйбарәләренә күрә «Гаһыд гатыйк» белән «Гаһыд җәдид»тә[2] искә алынган нәбиләренең китаплары»);

*4) **«Коръән кәрим айәт кәримәләренең могъҗиз ифадәләренә күрә гаиләдә хатын**» (*«Игелекле Коръәннең игелекле айәтләренең могъҗизалы гыйбарәләренә күрә гаиләдә хатын»);

*5) **«Коръән кәрим айәт кәримәләренең могъҗиз ифадәләренә күрә халәкать хәдисәсе**»* («Игелекле Коръәннең игелекле айәтләренең могъҗизалы гыйбарәләренә күрә яратылыш вакыйгасы»);

*6) **«Коръән кәрим айәт кәримәләренең могъҗиз ифадәләренә күрә әманәт илаһия хакыйкате**» (*«Игелекле Коръәннең игелекле айәтләренең могъҗизалы гыйбарәләренә күрә илаһи әманәтнең чын булуы»);

*7) **«Коръән кәрим айәт кәримәләренең могъҗиз ифадәләренә күрә тәгълим илаһи тарикълары**» (*«Игелекле

[1] Җәя эчендә китап исемнәренең тәрҗемәсе бездән.

[2] «Гаһыд гатыйк» – «Борынгы Килешү» (Ветхий Завет); «Гаһыд җәдид» – «Яңа Килешү» (Новый Завет).

Коръәннең игелекле айәтләренең могъҗизалы гыйбарәләренә күрә илаһи гыйлем бирелешенең юллары»);

*8) «**Коръән кәрим айәт кәримәләренең могъҗиз ифадәләренә күрә кәлям хакыйкате**» (*«Игелекле Коръәннең игелекле айәтләренең могъҗизалы гыйбарәләренә күрә Аллаһ сүзенең чын булуы»);

*9) «**Коръән кәрим айәт кәримәләренең могъҗиз ифадәләренә күрә инсаннарның кәрамәт илаһияләре**»* («Игелекле Коръәннең игелекле айәтләренең могъҗизалы гыйбарәләренә күрә кешеләрнең илаһи игелеклелеге»);

*10) «**Коръән кәрим айәт кәримәләренең могъҗиз ифадәләренә күрә Коръән кәрим хоруфаты**» **(***«Игелекле Коръәннең хәрефләре»);

*11) «**Коръән кәрим айәт кәримәләренең могъҗиз ифадәләренә күрә мәсахиф исламия әлифбасы**» (*«Игелекле Коръәннең игелекле айәтләренең могъҗизалы гыйбарәләренә күрә ислами әсәрләрнең әлифбасы»);

*12) «**Коръән кәрим айәт кәримәләренең могъҗиз ифадәләренә күрә исламның әүвәлге гасырларында холык-ы Коръән**» (*«Игелекле Коръәннең игелекле айәтләренең могъҗизалы гыйбарәләренә күрә исламның беренче гасырларында Коръәннең холкы»);

*13) «**Коръән кәрим айәт кәримәләренең нурлары хозурында фәлсәфә һәм тәсаввыф усульләре**»* («Игелекле Коръәннең игелекле айәтләренең нурлары яктысында фәлсәфә һәм суфичылык нигезләре»);

*14) «**Коръән кәрим айәт кәримәләренең могъҗиз ифадәләренә күрә хөҗҗәт илаһия нәдер?**»* («Игелекле Коръәннең игелекле айәтләренең могъҗизалы гыйбарәләренә күрә илаһи дәлил нәрсә ул?»*);*

*15) «**Коръән кәрим айәт кәримәләренең могъҗиз ифадәләренә күрә мәдәният гасырларында хилафәт исламия низамы**» (*«Игелекле Коръәннең игелекле айәтләренең могъҗизалы гыйбарәләренә күрә ислам дәүләтенең төзелеше»);

*16) «**Коръән кәрим айәт кәримәләренең могъҗиз ифадәләренә күрә соңгы заманның гыйбрәтле хәлләре хакында мөһим хатирәләр**» (*«Игелекле Коръәннең игелекле айәтләренең могъҗизалы гыйбарәләренә күрә заманыбызның гыйбрәтле хәлләре турында әһәмиятле хатирәләр»);

*17) «**Коръән кәрим айәт кәримәләренең могъҗиз ифадәләренә күрә Төрек мәдәни кануннары хакында әдәби гыйльми мөляхәзаләр**» (*«Игелекле Коръәннең игелекле айәтләренең могъҗизалы гыйбарәләренә күрә Төрек конституцияләре турында әхләкый-гыйльми уйланулар»);

*18) «**Коръән кәрим айәт кәримәләренең могъҗиз ифадәләренә күрә Мәсих ибне Мәрьям**» (*«Игелекле Коръәннең игелекле айәтләренең могъҗизалы гыйбарәләренә күрә Мәрьям углы Мәсих»[1]);

*19) «**Коръән кәрим айәт кәримәләренең могъҗиз ифадәләренә күрә Йа́җүҗ мәсьәләләренең ниһаъи хәлләре**»* («Игелекле Коръәннең игелекле айәтләренең могъҗизалы гыйбарәләренә күрә Йа́җүҗ мәсьәләләрен ахырына җиткереп хәл итү»);

*20) «**Коръән кәрим айәт кәримәләренең могъҗиз ифадәләренә күрә төрек таләбәләренә**» (*«Игелекле Коръәннең игелекле айәтләренең могъҗизалы гыйбарәләренә күрә төрки шәкертләргә»).

Бу исемлектән аңлашылганча, ватанын ташлап китәргә мәҗбүр булса да, Муса әфәнде үзе белән иң кыйммәтле байлыгын калдырмаган: әсәрләренең кульъязмаларын үзе белән алган. Галимнең тормыш юлында алга таба ачылган сәхифәләре бу хәзинәнең горбәтлекнең беренче елларында ук басыла башлавын күрсәтәчәк. Игътибар ителәсе тагын бер нәрсә – планлаштырылган әсәрләрнең темалары, эчтәлеге. Әгәр аларның һәммәсе Муса әфәнде үзе төзегән шул төзек тәртиптә нәшриятларның берсендә басылып чыгып дөнья күрсәләр иде, бүгенге көндә кулыбызда ифрат та әһәмиятле, энциклопедияләргә тиң гыйлем чыганагы, ирекле фикер

[1] Мәсих, әл-Мәсих (Аллаһ тарафыннан пакь кыйлынган) – Гайсә пәйгамбәр күздә тотыла.

чишмәсе, хикмәт хәзинәсе булыр иде. Китапларының киләчәгенә карата өметләре зурдан булган Муса әфәнде Берлиндагы нәшриятында басылып чыгачак әсәрләренең әһәмиятен милләт өчен, дин өчен файда китерүендә күргән: «*Әсәрләр өммәтнең игътибарына ирешсә, көчле теләкле төрки шәкертләргә азмы-күпме әхлакый-гыйльми файдалар бирә алса, борынгы заман ислам галимнәренең кыйммәтле хөрриятле фикерләрен, бүгенге мәдәният дөньясының (Көнбатышның) хөрмәтле, рухлы бөек фикерләрен төрки шәкертләргә тәкъдим итеп тору безнең ләззәтле теләкләребездер, шәрәфле вазифаларыбыздыр. Бөекләрнең нәсихәт теле белән әйтeләчәк юл күрсәтүләрен, шәкертләрнең файдалану юлы белән белдереләчәк үтенечләрен һәрвакыт зур шатлык белән кабул итәчәкбез, әлбәттә, иншаллаһ…*»[1].

Димәк, Муса әфәнде моңа кадәр чыгарган һәр китабын, беренче нәүбәттә, дини гыйлем эстәү юлында тырышлык куйган шәкертләргә атап язган булса, горбәтлектә дә шул эшен дәвам итеп, төрки мөселман милләтләренең киләчәгенә караган хезмәтләре белән аларның алгарышына үз өлешен кертергә тырышкан.

Берлинда чагында да Муса әфәнде Финляндиядәге дусты имам Вәли-Әхмәт Хәким хәзрәтләренә хатлар язып тора. Ул хатларда Муса әфәнденең көндәлек тормышы да, уйлары да, хисләре дә чагыла: «*Бүген 9 шәгъбан. Рамазан якынлашты. Очкычым булса иде мәчетегезгә һәркөн тәравих намазы кыйлмак өчен очар, төшәр идем. Берлин, гаять гүзәл бер мәркәздер. Ләкин мәчеттә намаз кыйлмак, рамазан төннәрен нурландырып җәмәгать белән тәравих намазларын үтәү сәгадәтләре биредә юк. Әгәр бүлмәмдә ислам китаплары диңгезенә күмелгән булмаса идем, намаз төннәрендә тәравих намазларында Аллаһка тәсбих кыйлмак өчен сезнең шәһәрегезгә барып бер ай кадәр торыр идем*».

Шул ук елларда Финляндиядә татар мәктәбе ачып җибәрүгә ирешкән дусларын котлау йөзеннән язылган хатта Муса әфәнденең анда уку-укыту эчтәлегенә һәм куелышына карата

[1] Өзек татар теленә тәрҗемә ителде.

биргән киңәшләре игътибарга лаек. Моннан тыш, мәктүптә Муса әфәнденең, бер яктан, борынгылыкка мөкиббән киткән кадимчелек, икенче яктан, модерн дип традицияләрдән тәмам ваз кичү кебек иҗтимагый һаваланууларга карата булган карашлары да чагылыш тапкан: «*Мәктәбегез ачылган икән, яхшы бер эш булган димәктер. Иң мөһим чарагыз, укытуны гаять кулай һәм гади итүдән, сәгатьләрен дә мөмкин мәртәбә азайтудан гыйбарәт булсын. Ягъни: 1) Мосхәф йөзеннән Коръән кәрим уку*[1]*; 2) гарәп әлифбасы белән йазу язу һәм 3) дин рөкеннәрен вә дин әдәпләрен яттан өйрәнү һәм үтәлешләрен белү кебек.*

*Бу нигез программа янында Фин мәктәпләрендә укытыла торган кулай хисап, башлангыч география дәресләрен дә төрек теле белән кабатласагыз, ислам мәмләкәтләрен, ислам дәүләтләрен дә төрекчә исемнәре белән өйрәтсәгез, боларга өстәп Төркиянең кабул иткән латин хәрефләрен дә мәктәп балаларына күрсәтсәгез бик яхшы булыр иде. Латин тарафдарлары бик ишәеп китте дигәнсез. Бу күренеш яхшы һәм дөрестер. Фәкать гарәп хәрефләренә дошманлык, гаҗәп, кайдан?*

*Борынгыдан бичара вә чаманы белмәгән адәмнәр, рус мәктәпләренә дошман иделәр. Кадим ысул тарафдарлары, голүмнең*[2]*, мөсбәт гыйлемнәрнең*[3] *дошманы иделәр. Бүген гарәп хәрефләренә дошманлык борынгы чирнең тагын да яман бер шәкеле түгелмедер?*

*Аяк киемнәрен һәр көн яңартучы, һәм дә ластик киеп аяк киемнәренең ялтыравын саклаган адәмнәрнең карашында* <u>*әгәр диннен вә ә*</u>*дәбиятның да бу аяк киемнәре кадәр дәрәҗә-*

[1] Мосхәф йөзеннән Коръән кәрим уку (мосхәф сәхифәләреннән Коръән уку) – күнгә, кәгазьгә яки язуны тоткан башка нәрсәгә кулъязма яки типографик басма рәвешендә теркәлгән Коръән мосхәф дип атала, ягъни мосхәф ул – матди төшенчә, ә шул матди йөртүчегә язу рәвешендә теркәлгән Коръән – мәгънәви төшенчә булып тора. Шуңа күрә «мосхәф йөзеннән Коръән уку» гаять тирән фәлсәфи мәгънәгә ия булган гамәл-гыйбадәт булып тора.

[2] голүм – биредә дөньяви дисциплиналар күздә тотыла.

[3] мөсбәт гыйлемнәр – дөньяви фәннәр.

*се бар исә, гарәп хәрефләрен дошман күзе белән күрү мөмкинмедер?*

*Мөтәвәлиләр карары белән мәктәп ачылганнан соң, сез – Финляндия мөселманнары – балаларыгызга төрек-латин хәрефләрен мотлакан*[1] *өйрәтегез. Шул ук вакытта Коръән әлифбасына дошманлык наданлыгы да сездә булмасын. Борынгы Госманлы императорлыгы дәверләрендә, шәйхелисламнарның кулларында, Төркия вә Төркестан төрекләре арасында, шулай ук ислам милләтләренең һичберсендә гарәп хәрефләре белән язып уку һөнәрләре, халык арасында гомумиләштерелмәве аркасында голумне, мәгарифне вә әдәбиятны гомумиләштерү уе белән Төркия кәмалист хөкүмәте төрек теле өчен латин әлифбасын бүген мәҗбүрият астында кабул итте исә, мондый хәерле бер чара, яки мондый зур бер сынау хакында ни өчен болай булды? Шундый булуы кирәк иде диюне дәүләт, табигыйдыр ки, кабул итә алмый. Бу бәлки ислам хөкүмәтләренең вә ислам милләтләренең һәрберсенә гыйбрәтле, куәтле олы бер сабак вә катгый бер кисәтү булып тора. Мустафа Кәмал хөкүмәте төрек теле өчен латин әлифбасын алуны кирәкле күрде. Төркия төрекләре ирекле төстә яңа әлифбаларын кабул иттеләр. Дин әлифбасы буларак Коръән кәрим әлифбасын да Төркия төрекләре кыяматкә кадәр сакларлар. Диннәренә, Коръән кәримнәренә, расүл вә Кәгъбәләренә олы ихтирам һәм тирән яратулары булган Төркия төрекләре иман вә дин куәте белән алтыйөз ел кадәр бер вакыт хәлифәлекнең бөтен мәшәкатьләренә түзеп, авыр бер йөк астында тавыш чыгармыйча йөз еллар буенча уку-язудан мәхрүм булуларына түзгән булсалар, диннәренә, Коръән кәримнәренә ярату куәте белән ике әлифбага түзү мәшәкатьләренә төрек балалары моннан соң да, әлбәттә, вә иншаллаһ, кыяматкә кадәр түзәрләр. Төркиядә әлифба мәсьәләсе мәгариф темасыдыр. Бу, иске бер мәсьәләдер. Әлифбаны төзәтү, аны яхшы бер хәлгә китерү максаты белән илле ел элек латин хәрефләре ляъихәсе, проекты, хилафәт хөкүмә-*

---

[1] мотлакан – шартсыз сурәттә; әлбәттә.

*тенә тәкъдим ителде. Ул заманнан бүгеннәргә кадәр төзәтү зарурилыгы уртада иде.*

*Бүген укый-язу белүне мәҗбүри кылу уе белән, инкыйлаб юлы белән, латин әлифбасы кабул ителде. Әлифбада икелек уртага чыкты. Фәкать берсе икенчесе белән янәшә, параллель буларак йөрүен дәвам итә ки, берсен хөкүмәт сакласа, икенчесен милләт саклый*».

Гомумән, Муса әфәнденең Финляндиядәге дин һәм кан кардәшләренә атап язган хатларыннан аның Аурупаның бу иленә карата нинди мөнәсәбәттә булуын аңлау җиңел. Мәсәлән, ул болай дип язган: «*Ислам милләтләренең яхшы вә йә яман бөтен хәлләрен күрдем. Бөтен җир йөзендә бүген иң рәхәт, иң имин, иң төзек дәүләтегезнең, хөкүмәтегезнең бөтен низамнарына һәр милләттән артык һәрвакыт ригая кыйлыгыз. Сездән әманәтле, сездән турылыклы, сездән дә эшлекле бер милләт якын тирәдә булмасын*».

Бөек дин галименең бу сүзләрен бүгенге көндә яхшы тормыш эзләп булсын, сугышлардан качып булсын, Аурупа илләренә, Көнбатыш цивилизациясенә күчеп китеп, шунда тамыр җибәрергә тырышкан мөселманнарның колакларына саласы иде, үзләрен кабул иткән, якты чырай күрсәтеп матди ярдәм белән тәэмин иткән Аурупа шәһәрләренең урамнарына чыгып, «Без динсез Көнбатышны шәригатьчә яшәтәчәкбез!», дигән шигарьләр яңгыратып, ләүхәләргә язып демонстрацияләр үткәреп йөрүче күзләреннән тирә-якка нәфрәт очкыннары сибелгән сакалбайларга ирештерәсе иде… Хәер, ни ишетмәс иделәр, ни уйга калмаслар иде, чөнки, пәйгамбәр әйткәнчә, әгәр Аллаһ тәгалә кешенең бәлагә таруын теләсә, ул аның акылын алыр. Әмма, ни генә булса да, Көнбатыш илләренең мөселманнар күпләп яши торган җирләргә әйләнүләреннән берничә дистә ел алдан диндәшләренә «кунак булсаң тыйнак бул» әдәбенә корылган киңәшләрен әйтүче безнең Муса әфәндебез иң беренче нәсихәтче булган һәм булып калачак.

## Беренче Төрек тарих конгрессында

1932 елның башында Муса әфәнде Берлин белән Һелсинки арасында йөреп тора. Ул арада 2–11 июльдә Төркия башкаласы Әнкарада Беренче Төрек тарих конгрессы үткәреләчәге турында хәбәр тарала. Муса әфәнде дә бу чараны күрергә тели. Бәхетенә, Йосыф Акчурадан аңа махсус дәгъвәтнамә килеп төшә һәм Муса әфәнде яңадан юлга чыга. Төркиягә барышлый ул Румыния аркылы уза, биредә үз вакытында Кырымнан күченеп килгән татарлар белән күрешә. Румыниядәге диндәшләре аңа яңа ачылган «Мәҗидия укытучылар мәктәбе»ндә мөгаллим эшен тәкъдим итәләр. Муса әфәнде бу турыда: «*Ул яхшы, заманча мәктәптә вазифа башкаруны хакыйкатән бик тели идем. Фәкать эчемдәге инкыйлаб максаты дөнья гизүемне таләп иткәнгә күрә, мине бу вазифадан баш тартырга этәрде*»,– дип язган.

Румыниядән Муса әфәнде Төркия башкаласы Әнкарага килеп төшә, конгресс утырышларында яңгыраган гыйльми чыгышларны тыңлый, чыгышлардан соң үткәрелгән фикер алышуларда катнаша. Бу вакыйгадан алган тәэсирләрен ул түбәндәге сүзләрендә чагылдырган: «*Беренче тарих конгрессында сәидә Әфәт ханымның*[1] *чыгышлары гүзәл бер сабак иде. Мөхтәрәм Йосыф Хикмәт Бәк*[2] *әфәнденең «Шәрыкта чигенеш сәбәпләре» дип исемләнгән чыгышын да зур игъти-*

---

[1] Әфәт ханым (Гайшә Әфәт Инан Узмай / Ayşe Afet Afet İnan Uzmay; 1908–1985) – төрек педагогы, тарихчы һәм җәмгыять белеме (социология) профессоры. Мостафа Кәмал Ататөрекнең тәрбиягә алган кызы. Төрек Җөмһүриятенең беренче тарих профессорларыннан булган Әфәт Инан Төрек тарих оешмасын (Türk Tarih Kurumu) оештыруда катнаша һәм еллар дәвамында аның белән җитәкчелек итә. Беренче төрек тарих конгрессында мәктәп укытучысы буларак катнашып, чыгышының эчтәлеге һәм тирәнлеге белән Бигиевнең хуплавын яулый. Әфәт ханымның Беренче төрек тарих корылтаенда ясаган чыгышын укырга мөмкин: https://drive.google.com/file/d/0B7liBn5XLsAfaW1PbnlqSXpsZ0k/view

[2] Йосыф Хикмәт Бәк (Yusuf Hikmet Bayur, 1891–1980) – Төркия дәүләт эшлеклесе, сәясәтче, тарихчы галим.

*бар белән тыңладым. «Төрекчелек» дип һаваланууларының җилләре аның фикерләре дөреслеген, азмы-күпме, башка тарафка авыштырса да, бөтен җыелышларның нигез темаларын тәшкил иткән «ана хатлар»ны*[1] *бераз киңәйтү буларак, бәлки кабул ителерлек бер нәрсәдер. Тыйнак вә басынкы төрекләрнең каннарында һәрвакыт терелеш иксирләрене*[2] *күреп тә, исламның рухында бары тик алгарышка киртә булган үзенчәлекләрне, бары тик торгынлык куәтләрене тапкан Йосыф Хикмәт Бәк әфәнде, ислам диненең гомуми хокукларын аңлатканда һәм кыскача бәяләгәндә, фикер алышу забытларының*[3] *506 нчы сәхифәләрендә китерелгән стенограммаларын, кимендә, бары тик Төркия хуҗаларына, аларның да, бәлки бары тик җаһилләренә карата атап әйтергә рәхим итсәләр иде, дөреслеккә ирешү мөмкинлекләре тагын да артыр иде.*

*Коръән кәрим кебек бөек бер китапта, ислам кебек бөек бер диндә алгарышка юл куймый торган торгынлык куәтләрен, артта калганлыкка тартылу кебек үзенчәлекләрне күрү, аерым алганда, төркиләр кебек тарихның иң алдынгы, иң егәрле милләтләрне артта калганлыкта гаепләү булып чыга түгелме?*

*Аллаһның* (ليس لك من الامر شىء)[4] *кебек,* (فذكر انما انت مذكر لست عليهم بمسيطر)[5] *кебек,* (انما انا بشر مثلكم)[6]*, кебек хитабларын, иң әүвәл*[7]*, пәйгамбәренә юллаган бер китапның пәйгамбәренә*

---

[1] «ана хатлар» – конгрессның тематик чикләре.

[2] иксир (гарәп.: әл-иксир) – шифалы эчемлек; сыек дару; иксирләрнең кайчак тылсымлы сыйфатларга ия булуларына ышану бар; (эликсир).

[3] забыт (гарәп.) – нинди дә булса чыгышның, сөйләшүнең, фикер алышуның кәгазьдә теркәлгән нөсхәсе, протокол.

[4] «Синең бу эшкә катнашың юк» (Коръән, 3:128).

[5] «Шулай булгач, син исләренә төшерт, син искә төшертүче ич» (Коръән, 88:21).

[6] «Дөреслектә, мин сезнең кебек үк бер кешемен» (Коръән, 18:110).

[7] иң әүвәл – беренче нәүбәттә (чиратта); иң элек; башта.

*һәм хәлифәләренә мотлак хакимият[1] хас булса, андый ирекле вә шартлар белән чикләнмәгән хакимиятнең бөтен куәтләрен үзенә сыйдырган вәкиллек низамына бер исем табу мөмкинме?*

*Бездән күбрәк сезгә мәгълүмдер ки, олы иманлы соңгы дәвер мәдәниятенең мәгърифәте белән тәртипкә салынып, инсаннарга хөррият нигъмәтләрен[2] игълан иткән хокук-е бәшәр[3] бәян-нәмәләре,[4] сезгә мәгълүм булган Коръән кәрим белән чагыштырганда, диңгездән бер тамчыдыр. Болай булганнан соң да Коръән кәримне торгынлыкның, артта калуның сәбәбе итеп күрү көфран[5] кебек бер кирелек булмасмы?*

*Динне дөньядан аеру бүгенге мәдәниятнең үзенчәлекле сыйфаты түгел, бәлки исламның борынгы мөһим гакыйдәседер. Ләкин Коръән кәримдә бәян ителгән тормыш мәслихәтләренә күпкә ятышлырак булган төзек вә эзлекле хокуклар, Эсвичрә[6] кануннары кебек, мәдәни яшәеш кануннарыдыр. Тормышның мәслихәтләренә раһбәр[7] була алырлык һәр канун мәдәни канун була. Коръән кәримдә урын алганга күрә генә канун мәдәни канун булудан туктамый. Һәм, киресенчә: мәдәният кодексларында теркәлү бәхете белән генә теге яки бу канун мәдәни канун була алмый. Мәслихәте тагын да югарырак дәрәҗәдә була алган борынгы канун хәзерге заман кануннарының һәрберсеннән күпкә мәдәнирәк була ала.*

*Тарихта зур гыйбрәт булган ике күренеш бар: 1) берсе – «Инҗил»ләре белән соңгы заман Гаребе, 2) икенчесе – Коръәне белән хәзерге Шәрык. Боларның беренчесе Изге Китабында булмаса да, [аек акыл] хөкемнәре белән гамәл итеп, аны бөтен телләргә тәрҗемә итеп, бөтен җир йөзенә таратып,*

[1] мотлак хакимият (гарәп.) – һичнәрсә белән чикләнелмәгән хакимият; (абсолютная власть).

[2] нигъмәт (гарәп.) – нинди дә булса яхшы нәрсә, халәт яки күренеш.

[3] хокук-е бәшәр (гарәп.) – кеше хокуклары: бәшәр – кеше.

[4] бәян-намә (гарәп.– фарс.) – рәсми игълан, белдерү.

[5] көфран (гарәп.) – хурлау; танымау, кире кагу.

[6] Эсвичрә – Швейцария.

[7] раһбәр (гарәп.) – әйдәп баручы, әйдаман, лидер.

*үзенең Китабын ихтирам итү бәрәкәте белән бөтен җир йөзенең падишаһы булды. Боларның икенчесе, ягъни Шәрык, үзендәге Китапның олы иршадларын[1] санга сукмыйча, ахыр чиктә, Китапның үзен дә тәмам аяк астына ату гөнаһы аркасында бөтен җирләреннән бөтенләй мәхрум калды да, бүгенге бөек кыямәт тәэсире белән уянып китте. Гареб дөньясы бүген бөтен бөек тетрәнүләргә юлыгып, тәмам аптыраштa калды. Шәрык исә гасырларча исәпкә алынмаган мөкаддәс Китабын олы иманлы газиләренең[2] хикмәтле иршады белән кулына алды да, аны бөтен телләргә булмаса да, кимендә үз теленә тәрҗемә итеп, иман белән тулы йөрәгенә салды. Әҗәткә алынган мал рәвешендә, Гареб хәзинәләрендә сакланган, үзенең элек санга сугылмаган мәдәни кануннарын да кире кайтарып, данлы-шанлы борынгы олуг тарихларын тагын да шәүкәтле бер шәкелдә ватанына кире кайтару турындагы килешү белән, ислам милләтләренә үрнәк рәвешендә, Мәгърибтән күтәреләчәк кояшка таба юнәлде[3].*

*Мин хәзерге вазгыятьне әнә шулай күрәм, яки аңлыйм. Бөек ике галәмне үзара чагыштырганда, шушындый кыска гына бер нәтиҗәгә киләм».*

Әнкарага бу килешендә Муса әфәнде үзенең күптәнге дусты Йосыф әфәнде Акчура белән генә түгел, Русиядән элегрәк качып киткән Садри Максуди кебек күптәнге аркадашлары белән дә күрешә, яңа кешеләр белән таныша, Төркиядәге сәяси-иҗтимагый вазгыятьне үз күзләре белән күреп күзәтә, нәтиҗәләр ясый. Акчура әфәнде ул вакытта Төркия президенты Мостафа Кәмал Ататөрекнең киңәшчесе була. Аның ярдәменнән файда күреп, Муса әфәнде илбашы Ататөрек белән күрешеп сөйләшү ниятен тормышка ашырырга тырыша, әмма бу эш барып чыкмый, чөнки ислам динен җәмгыять һәм дәүләт тормышыннан мөмкин кадәр аерырга тырышкан

[1] иршад – дөрес күрсәтмә; дөреслеккә ирештерүче киңәш.

[2] гази – үзенең каһарманлыгын сугыш кырында күрсәткән һәм җиңүгә ирешкән батыр.

[3] Мәгърибтән күтәреләчәк кояшка таба юнәлде – Ахыр заманда Кояшның көнбатыштан калкачагы турындагы хәбәргә киная.

Төркия президенты ул диннең олылыгын һәм бөеклеген раслаучы галим белән көрәшүне кирәксез дип таба.

## Яңадан Хиҗазда. Гобәйдулла әс-Синһди

1932 елда Төркияне зиярәт иткәннән соң, Муса әфәнденең Хиҗазга киткән булуын чамаларга мөмкин. Бу турыда, беренчедән, Йосыф Уралгирәйдән укып беләбез. Үзенең китабында ул Муса әфәнденең Мәккәдән язган хатларын китергән. Хатларның эчтәлегендә, моны раслаган мәгълүматтан тыш, 1932 елда остазның Мәккәдә булуы турындагы хәбәр Әхмәт Канлыдәрәнең китабында да очрый.

Муса әфәнденең Мәккәдән язган хатыннан бер парча китерик: «*Мин сыйххәттәмен. Гаять сәламәттәмен. Шәкертлектә дәвамлы эшләүләрем яхшы вә бәрәкәтле иде. Күп укыдым. Зур-зур китап хәзинәләрен укып чыктым һәм файдаландым.*

*Бөтен җирләрдә мәдрәсәләр ябылганнан соң, Русиядә, Төркестанда дини, гыйльми бер мәдрәсә ачу юлындагы гайрәтләрем нәтиҗә бирмәде исә дә, ягъни зур өметләремнән беренә ирешә алмадым исә дә, Аллаһ мине шәкертлек шәрәфләреннән мәхрүм итмәде. Сәяхәтем шәкертлек сәяхәте булды. Һәрбер әсәремдә фәкыйһләрнең фикерләрен уяндыру максаты белән вак-төяк сүзләр яза идем.* ***Максатым – ислами фикерләрдә инкыйлаб хәрәкәтләрен барлыкка китерү****. Бүген моңа өметем, омтылышым һәм теләкләрем артты. Ислами гыйлемнәрдә, дини фикердә кечкенә һәм зур инкыйлаб хәрәкәтләрен ислам дөньсында ислам мәмләкәтләренең берсендә уяндыру бүген миңа якын бер өмет булып калды.*

*Бу көннәрдә берничә әсәремне бастырачакмын. Һиндестанда, Мисыр, Сүрия, Гыйрак вә Һиҗазда иншаллаһ таралыр.* ***Мөгаен, Төркиядә вә яки Һиндестанда дини, гыйльми бер мәктәпкә нигез салырмын****. Ярдәмчем Аллаһтыр. Омтылышларым зурдыр. Һиндестан бөекләренең ишарәләре дә, күренеп торган теләкләре дә бар. Бурса вә яки Конья кебек Төркия шәһәрләренең берсендә голүм исламия дәресләрен*

*хөкүмәт рөхсәте белән ачылуы ихтималлары да якындыр. Тырышлык вә гайрәтемдә ныклык күрсәтә алсам, рөхсәтнең бирелүе мөмкиндер. Бу серләремне сезгә ачам. Аллаһ җәллә җәлалүһу хәзрәтләре тырышлыкларымны киң рәхмәте белән иншаллаһ кабул боерыр.*

*Быел тулы бер хәрарәт*[1] *белән хаҗ кыйлачакмын. Иншаллаһ мөкаддәс җирләр хозурында, мөбарәк илаһи шигарьләр эчендә Финляндия мөселманнарының һәрберенә догалар кылырмын. Һәрберенә халис, тирән шөкерләрем әлбәттә дәвамлыдыр. Үзсүзлелек куәте белән дә, интизар юлы белән исә дә Кәгъбә хозурында бер елдан артык игътикяф иттем. Анда гаять киеренке бер сурәттә эшләдем. Коръән кәрим хакында 3000 сәхифәлек кадәр мәгълүмат тупладым. Каһирә көтепханәләрендә 20 ай кадәр эшләгән идем. Аллаһ гомеремне бераз озайтачак булса, Аллаһның ярдәме белән Коръән кәрим хакында 2–3 китабымны иншаллаһ бастырырмын. Бирелән мөгаен туп-туры мөкаддәс Мәдинә шәһәренә хәрәкәт итәрмен. Иманлы калебемнән олы хәсрәтләремне, гөнаһлы күземнән сәлләр кебек агачак яшьләремне пәйгамбәр әфәндемез хозурында бераз түгәрмен».*

Хаттан аңлашылганча, Муса әфәнде гомере дәвамында кимендә ике мәртәбә хаҗ кылган. Әмма хатның кайсы елда язылганлыгы күрсәтелмәгән. Әгәр ул 1932 елның июль-август айларында Мәккәгә китеп урнашкан булса, мәктүбендәге «*Кәгъбә хозурында бер елдан артык игътикяф иттем*» дигән сүзләреннән аның изге шәһәрдә кимендә 1933 елның җәенә кадәр вакыт үткәргән булуы аңлашыла. Болай булганда, Муса әфәнде хаҗ йоласын икенче мәртәбә 1933 елның апрель башында башкарган булып чыга.

Мәккәдә үткәргән бер ел дәвамында Муса әфәнде ул чакта шунда яшәгән атаклы дин галиме Гобәйдулла әс-Синһди белән дә күрешә. Бу очрашуның нинди нәтиҗәгә китерүен

[1] хәрарәт – эсселек. Сүз контекстка туры килмәгәнлектән биредә хата булып, чынлыкта хөррият сүзе булырга тиешлеге турында фараз йөртеп була. Бу очракта җөмлә Быел тулы бер хөррият (иреклелек) белән хаҗ кыйлачакмын, дип укылачак.

бәян итәр алдыннан, Гобәйдулла әс-Синдһи кебек олуг шәхес турында ачыклык кертергә кирәк.

Гобәйдулла әс-Синһди (1872–1944) – дин галиме, фикер иясе, ялкынлы инкыйлабчы, Һиндестан мөселманнарының милли азатлык көрәше тарихында тирән эз калдырган шәхес. Чыгышы белән ул Һиндестандагы Пәнҗаб вилаятендә борынгыдан сикһ динен тотып яшәгән атаклы бер нәселнең вәкиле була. Шуңа күрә туганда аңа традицион Бута Сингһ Уппал исеме бирелә. 15 яшендә Бута Сингһ ислам динен кабул итә һәм үзенә Гобәйдулла Синдһи исемен ала. Дини гыйлемне ул Диюбәнд шәһәрендәге мәшһүр Дарел-голүм югары мәдрәсәсендә ала. 1909 елдан ул әлеге уку йортында бик популяр булган панисламчылык хәрәкәтенә кушыла. Беренче бөтендөнья сугышы елларында әс-Синдһи Мәүләнә Мәхмүд Әл-Хәсән һәм башка фикердәшләре белән бергә сәяси эшчәнлекне дәвам итә. 1913–1920 еллар арасында Диюбәнд мәдрәсәсе зыялылары Һиндестанны, бигрәк тә андагы мөселманнарны Бөекбритания колониаль изүеннән азат итү максаты белән яшерен сәяси оешма оештыралар. Хәрәкәтнең максатлары оешманың юлбашчыларыннан берсе булган әс-Синдһи кулы белән ефәк тукымада язылганга күрә, оешмага «Ефәк хат хәрәкәте» дигән исем бирелә. Максатларына ирешер өчен, алар Госманлы империясе, Әфганстан әмирлеге һәм Алман (Герман) империясе белән килешү корып эш итәргә ниятлиләр. Полиция бу оешманың эзенә төшкәч, Гобәйдулла һәм аның белән бергә башка һинд мөселман инкыйлабчылары Һиндестаннан китеп, Әфганстанга – бу илнең әмире Ташкентта туган үзбәк кешесе Хәбибулла Ханнан ярдәм сорарга баралар. Хәбибулла Хан (1872–1919) һиндестанлы дин кардәшләренә ачык чырай күрсәтеп, 1915 елның декабрь аенда Әфганстанда Һиндестан вакытлы хөкүмәте (ҺВХ) төзергә мөмкинлек бирә. ҺВХ рәисе итеп Раҗа Махандра Пратаб (1886–1979) сайлана. Пратаб җитәкчелегендә ҺВХ әгъзалары Алмания ярдәме белән Һиндестанда революция оештыру планнары төзиләр һәм бу планнарны тормышка ашыруга багышланган эшкә керешәләр. ҺВХ әгъзалары Әфганстанда

Беренче дөнья сугышы беткәнгә кадәр торалар. 1919 елның февраль аенда Хәбибулла Хан атып үтерелә һәм Әфганстанда эчке сәяси халәт үзгәрә. Бу шартларда ҺВХ әгъзалары бу илне ташлап китүне хәерлерәк күрәләр. Хәрәкәтләрен дәвам итәр өчен, ярдәм эзләп, инкыйлаб кичергән Русиягә китәләр. Шул елларда алар Муса әфәнде белән дә танышалар. Гобәйдулла әс-Синдһигә килгәндә, Русиядән соң ул Төркиядә һәм башка берничә илдә яшәп ала, соңыннан Хиҗазга барып, 14 ел гомерен шунда үткәрә. Хиҗазда яшәгән дәвердә ул ислам фәлсәфәсен һәм 18 гасырда Һиндестанда күренекле дин галиме булларак танылган Шаһ Вәлиулла Дәһләвинең (1703–1762) мирасын өйрәнә.

Ике олуг галим 1932 елда Мәккәдә очрашканнан соң, Әс-Синдһи Муса әфәндене Вәлиулла Дәһләвинең карашлары һәм гаять үзенчәлекле гыйльми методологиясе белән таныштыра, аны шул галим ысулына корылган Коръән тәфсире язу идеясе белән мавыктыра. Ике галим, бу саваплы идеяне тормышка ашырырга карар кылып, эшкә тотыналар. Иртәнге намаздан соң Гобәйдулла тәфсирен башлый, шулай итеп өйлә намазына, кайчак икенде намазына кадәр аны сөйли, Муса әфәнде исә Гобәйдулла сөйләгән тәфсирне язып бара. Шул рәвешле 115 көнне туктаусыз эштә үткәрәләр дә тәфсир язуны 1933 елның гыйнвар аенда тәмамлыйлар. Җәмгысы 2400 кульязма сәхифәдән гыйбарәт булган хезмәт әзерлиләр.

Муса әфәнде бу юлы Хиҗазда яшәгәндә нәрсә исәбенә көн күргән дигән сорауга җавап итеп, аның мәдрәсәләрнең берсендә шәкертләргә һәм кызыксынуы булган башка гыйлем эстәүчеләргә ун Коръән кыйраәтен укытуы турында фараз кылып була. НКВДда язган протоколларның берсендә Муса әфәнде үзе турында «Я лучше всех знаю Коран» дип юкка гына язмаган. Аның Коръәнгә кагылышлы белеме Изге китапның тарихы, җыелуы һәм теркәлүе белән генә чикләнмәгән. Муса әфәнде ислам дөньясында борынгыдан йөзек кашыдай сакланып килгән Коръән укылышларын да, ягъни кыйраәтләрне белгән. Бездә Коръән хафиз булу зур мәртәбә. Әмма яттан гына белү аз. Яттан белгән Коръәнне хафиз го-

мере буе бер кыйраәт белән генә укып та әлләкем булып йөри ала. Чынлыкта җиде төрле кыйраәтне белү олы мәртәбә булып санала. Ә Муса әфәнде андый кыйраәтләрнең унысын, ягъни сәхабәләр заманында ук формалашып, шуннан бирле сакланып килгән һәр кыйраәтне белгән. Сүз уңаеннан, кушымтада Муса әфәнденең Коръән кыйраәтләренә багышланган бер әсәреннән кыска гына парча китерү урынлы булыр[1].

## Яңа нәшрият, яңа китаплар

1933 елның яз айларында Муса әфәнде Хиҗаздан Алманиягә кайта һәм Шәркый Төркестандагы һәм Финляндиядәге дусларының ярдәме белән Берлинда W 15, Kaiserallee 204 адресы буенча урнашкан бинада, ниһаять, үз нәшриятын ачып, китап бастыру эшен башлап җибәрә. Бу яңа нәшриятта 1933 елда басылып чыккан тәүге китаплардан булган «***Тарихның онытылмыш сәхифәләре***»ндә Муса әфәнде «Ислам милләтләренең олы дикъкатьләренә» исемле язма урнаштыра: «*Берлинда, иң зур мәдәният мәркәзендә ислам халыкларының телләрендә гарәп хәрефләре белән нәшер кылыначак әдәби һәм дини әсәрләргә бер үрнәк буларак: 1) берсе «Тарихның онытылмыш сәхифәләре», 2) икенчесе «Коръән кәрим айәт кәримәләренең могъҗиз гыйбарәләренә күрә, Йаэҗүҗ» мәсьәләләре» – бу ике әсәрне ислам милләтләренең олы дикъкатьләренә, төрек шәкертләре файдалансын өчен бу юлы тәкъдим иттек.*

*Сәяси юнәлешебезне дә, дини кыйблабызны да, милли максатыбызны да, әдәби идеалыбызны да әлеге ике әсәр ачыктан-ачык күрсәтә.*

*Бөек инкыйлаб туфаннары аркасында фикере вә каләме кирәксез калып, телләре хәрәкәтсез калган иҗтиһад әһеленең, әгәр теләсәләр, мөһим һәм файдалы әсәрләрен, ин шәъә Аллаһ, нәшер итәрбез.*

*Егерме-утыз вак-төяк мондый әсәрләр бер-бер артлы чыкканнан соң, дәртле өммәт әгәр рәгъбәт итсә*[2]*, бу алтын*

[1] Карагыз: III Бүлек. 20: Кыйраәт тарихы.

[2] рәгъбәт итәргә – бык нык теләргә.

*чылбырыбыз, Аллаһның ярдәме белән, гыйльми мәҗәлләнең чыгуына бер зиннәт ителеп, таралышына да бер чара була. Ин шәъә Аллаһ. Җиһадыбыз фи Аллаһтыр*[1]*, иҗтиһадыбыз халис ли-вәҗһи Аллаһ*[2]. *Саф ихласылыгыбыз гыйсмәттер*[3].

*Аллаһ, җәллә җәлалүһу*[4]*, хәзрәтләренең ярдәменә, Рауза-и сәгадәт*[5] *ярларының бәрәкәтле бәхетле әгъзаларына, олуг өммәтнең бөек тырышлыгына, төрек шәкертләренең теләк-омтылышларына таяндык»*[6].

Берлиндагы нәшрият белән бәйле башлам бәрәкәтле булып, чыннан да, шактый уңышлы эшли һәм 1933 елда Муса әфәнде биредә берничә әсәрен бастырып чагара. Андыйлардан, инде искә алынган «*Тарихның онытылмыш сәхифәләре*» белән «*Коръән кәрим айәт кәримәләренең могъҗиз гыйбарәләренә күрә, Йа́җүҗ*» китаплары; әлегә кадәр табылмаган «*Коръән кәрим айәт кәримәләренең могъҗиз ифадәләрендә, сәмиларның әнбияләре, сәмави китаблары*» исемле әсәр; һәм, ниһаять, «*Коръән кәрим айәт кәримәләренең нурлары хозурында хатын*» исемле энциклопедик рухта язылган гаять тирән мәгънәле хезмәт.

Китапларны басмага әзерләгән чакта Муса әфәнде Берлиннан Финляндиядәге имам Вәли-Әхмәт хәзрәткә язган хатында болай дигән: «*…бастырмак өчен ике китабымны бүген матбагага бирдем. Рөхсәт итсәләр бер китабымның йөзенә «фәлан әфәнде һиммәте белән», икенчесенең йөзенә дә «фәлан әфәнде һиммәте*[7] *белән басылды» сүзләрен язар идем. Үзләреннән рөхсәт алып миңа белдерсәң яхшы булыр иде*», дип үтенгән. Икенче бер хатта: «*Рөхсәт эстәдем. (Фәлан) әфәнде: «бер комачау юк» дигән булса иде, шул җитәр*

[1] җиһадыбыз фи Аллаһтыр – рухи көрәшебез Аллаһ өчендер.

[2] иҗтиһадыбыз халис ли-вәҗһи Аллаһ – дин даирәсендәге тырышлыгыбыз чын күңелдән Аллаһ ризалыгы өчендер.

[3] гыйсмәт – сафлык, намуслылык; гөнаһсызлык.

[4] җәллә җәлалүһу – Аның бөеклеге бөектән бөек булды.

[5] Рауза-и сәгадәт (Бәхет гөлбакчасы) – Мөхәммәт пәйгамбәрнең (ﷺ) Мәдинәдәге ишле гаиләсе.

[6] Татар теленә тәрҗемә ителде.

[7] һиммәт – тырышлык.

*иде. Бу Финляндия җәмәгатенең мөхтәрәм затларына эчтән килгән ихтирамымның бер чагылышы булачак иде. Һиндестанда, Әфганстанда вә Төркестанда укылачак бер әсәр өстенә атларының язылып аларга сайгы*[1] *күрсәтелүе бушка түгелдер. Максатым сайгы иде. Мин бик теләдем. Алар дәшмәделәр. Карар аларныкыдыр. (Фәлан) әфәнделәрнең һиммәтләре белән нәшер кылынды дисә идем, әлбәттә, бер кыенлык булсам иде…*»

Аңлашылганча, Муса әфәндегә ярдәм иткән кешеләрнең кайберләре җавап-фәлән бирмәгәннәр. Нәтиҗәдә «*Тарихның онытылмыш сәхифәләре*»[2] исемле китапның гонван (титул) сәхифәсен «*Финланд мөселманларындан: Гыймад әфәнде Җәмал һиммәтейлә табыг кыйлынды*», ә «*Коръән кәрим айәт кәримәләренең могъҗиз гыйбарәләренә күрә, Йаәҗүҗ*»не «*Кәшгарлык мәшһүр мөхтәрәм Мөхийетдин Җан ахунд баба Корбан җәнабларының һиммәтейлә тәбыгъ кыйлынды*» дигән шөкеранә сүзләре бизәп торса, «*Коръән кәрим айәт кәримәләренең нурлары хозурында хатын*» китабында мондый мәгълүмат күрсәтелмәгән. Инде бу әсәрләргә бер күзәтү ясап узыйк.

«*Тарихның онытылмыш сәхифәләре*»н Муса әфәнде казый Габдерәшит хәзрәт Ибраһимның хатирәләре нигезендә тарихи очерк жанрында яза. Чынлыкта исә бу әсәр Госманлы иленең мөһим тарихи вакыйгаларын яктырта, аларның махсус сурәттә бозылып күрсәтелгән һәм, хәтта, оныттырылганнарын бәян итә торган җитди фәнни тикшеренү булып танылырга лаеклы. Бу китапның Берлиндагы нәшриятта беренчеләрдән булып басылуы да Муса әфәнденең аңа никадәр әһәмият бирүен чагылдыра. Бу басманың башыннан «*Солтан Газиз шәһитлегенең асыл сәбәбе ни иде?*» дип аталган татар теленә тәрҗемә ителгән бер парчасын китерәбез: «*Тарихның бик мөһим сәхифәләре онытылган, кайчак аңлы рәвештә сы-*

---

[1] сайгы – ихтирам.

[2] Муса Җаруллаһ. Тарихның онытылмыш сәхифәләре. Беренче халка: Солтан Газизнең шәһадәтенә асыл сәбәб нә иде? Берлин, 1933. 18 б.

*зып атылган, яки сәясәт гыйфритләренең[1] сихерләре белән яшерелгән булырга мөмкин. Габдел-Газиз солтанның[2] шәһит булуы да тарих сәхифәләрендә бер сер кебек булып калган. Сарай тарихчылары Газизнең исрафларыннан, рус илчесе кулында ихтыярсыз уенчык булып, ахмаклыгы, олы башбаштаклыгы турында әйткәннәре мәгълүмдер. Тарихчыларның хаклы булу ихтималлары инкяр кылына алмаса да; сәясәт уеннарыннан гафил булу ягыннан, безгә ирешкән хәбәрләрне яки уйлап чыгарылган имеш-мимешләрне кабул итү хосусларында азмы-күпме аклана алсалар да, мондый мәсьәләләрне тикшерү һәр төрекнең хакыдыр, аек акыл, үткен күз әһелләренең вазифаларыдыр. Солтан Газиз шәһитлегенең серләрен бераз хәл итә алачак хатирәләр миндә бар. Шуларның кайберләрен мин биредә бәян итәчәкмен.*

*Беренчедән, солтан Газизнең улкадәр ахмак булмавы хакыйкатькә якынрак. Бу җитешсезлек турындагы имеш-мимешләр ап-ачык бер уйдырмадыр. Падишаһларның акыллары, дәүләтләрнең кодрәтләре хәрби куәтләре белән билгеләнә. Госманлы дәүләтенең иң куәтле хәрби диңгез көчләре солтан Газиз дәверендә иде. У вакытта Төркия хәрби диңгез көчләре ягыннан дөньяда икенче дәрәҗәдә иде. Монтазыйм[3] бишйөз меңлек гаскәренең дә барлыгы расланган иде. Ярты миллион ихтыяри гаскәр җыярга да Төркиянең ул вакытта көче җитә иде. Газизнең шәһит булганыннан соң шул ук куәт Туна[4] сугышында барлыгын күрсәткән иде. Дәүләт эшләренә игътибар вә әһәмият бирә иде. Мисырга, Аурупага кылган сәяхәтләре дә, әлбәттә, файдасыз түгел иде. Һәр-*

---

[1] гыйфрит – бик куәтле җен. Әлеге мәхлүкъ Коръәннең 27 нче сүрәсенең 39 нчы айәтендә искә алына.

[2] Габдел-Газиз солтан (1830–1876) – Дәүләти Госмания Галия белән 1861–1876 елларда идарә иткән падишаһ. 1876 елны май аеның 30 ында гыйсьянчылар тарафыннан тәхетне калдырырга мәҗбүр ителә, берничә көннән (июнь аеның 4 ендә) шәһит була. Рәсми хәбәрләргә күрә, Габдел-Газиз үз-үзен үтергән булып чыга.

[3] монтазыйм – тәртипкә салынган; рәсми (регуляр).

[4] Туна (طونة) – Госманлы дәүләтенең Дунай елгасы буенда урнашкан биләмәләре.

*никадәр рәсми кәгазьләр кулымда булмаса да, Газизнең сәяси фикерләренә, күргән чараларына кагылышлы халык арасында таралган риваятьләр әһәмиятле хакыйкатьләр турында кыймммәтле шаһид була ала. Әкият булуы да ихтимал. Ләкин халыкның әкиятләре дипломатларның уйдырма гайбәтләреннән дөресрәк булырга мөмкин.*

*Солтан Газиз дәверендә ил халкының саны кырык миллион кадәрдер дип фараз кылына иде. Әдирнә вилаятен*[5] *исәпкә алмаганда, Төркиянең Аурупа өлешендә халыкның күпчелеге аулах*[6]*, хорват, болгар, каратаг, серб, мажар кебек, һәммәсе христианнар иде, һәр минутта гыйсьяннарга әзер милләтләр иде. Ул вилаятьләрнең мөселманнары исә, гаять җаһил, күбесенчә фәкыйрь иделәр. Ләкин мөселман булганнарына күрә, милли хакимиятнең куәте астында мин-минлекләре булдыкча куәтле, диннәренә мәхәббәтләре дә көчле иде. Башка тарафтан исә, христиан дәүләтләре белән күрше булганга күрә, мәмләкәт эчендә һәрҗирдә христианнарның миссионерлары, раһибләре*[7]*, папаслары*[8] *һәр тарафтан үтеп кергән иделәр, зур тырышлык белән һәм дини дошманлыкларын, һәм дә сәяси каргышларын аңлаталар, тараталар иделәр. Халыкта дәүләтнең зарарына карата усаллык тәрбия итәләр иде, христианнарны таркату эшләренә дәгъвәт итәләр иде.*

*Чит дәүләтләрнең мөселманнар яшәгән вилаятьләренә бер төрек кешесе бара алмый иде. Канун тарафыннан тыелмаса да, гамәлдә тыелган эш иде. Төркия дәүләте андый урыннарга хәтта бер консул да юллый алмый иде. Казанда бер консул булдыру өчен, Төркия хөкүмәте никадәр мәртәбә мөрәҗәгать иткән булса да, Русия хөкүмәте моңа юл куй-*

---

[5] Әдирнә вилаяте – Госманлы Дәүләт-и Галиясенең территориаль-административ бүлекчәсе. Заманында хәзерге Төркиянең Аурупадагы өлешләрен, Көнбатыш Фракиянең шәрык өлешен һәм хәзерге Болгариянең бер өлешен үз эченә алган. Мәкалә язылган дәвердә вилаятьнең мәйданы 67 800 км², тәшкил итеп, халык саны 80 000 тирәсндә булган.

[6] аулах – Валахия вилаятенең халкы – румыннар.

[7] раһиб – монах.

[8] папас – поп.

*мады. Төркия вилаятьләрендә исә, рус консуллыклары, мәктәпләре һәрҗирдә бар иде. Һәрбере фетнә учаклары иде.*

*Чит дәүләтләрнең гражданнары булган мөселманнар, мөселманлыкка күчәргә теләк белдергән адәмнәр, Төркия мәмләкәтләренә килгән чакта, христиан хөкүмәтләренең химаясе белән горурланалар иде. Тунис, Фәс*[1]*, Җәзаир*[2] *гарәпләре француз химаясе белән, Русия мөселманнары рус химаясе белән горурланып, «Үзебезнең русыбыз!», «Безнең русыбыз!» – дияләр иде. Хәтта бүген дә шулай. Хәтта христиан хөкүмәтләренең эзәрлекләүләреннән качып, диннәрен саклап калу өчен Төркия җирләренә һиҗрәт итүчеләр була торып та, Төркия кануннарына итәгать итмәү максаты белән, гражданлык паспортларын саклыйлар иде, ләдәйел-ийҗаб*[3] *консуллыкларына мөрәҗәгать итеп яклау эзлиләр иде.*

*Солтан Газиз бөтен бу хәлләрне белеп, чит илләрдәге мөселманнар белән мөнәсәбәт кору юлларын эзли иде. Бер мисал: 1870 елда Петропавловск*[4] *шәһәреннән Габдел-Бари ахунд*[5] *Хиҗазга барышлый, хәлифә*[6] *хозурына кабул кылынып, олы хөрмәт күргән иде. Ватанына кире кайтканда Сарай-е Һумаюннарын*[7] *зиярәт кыйлу әмерен дә алган иде. Хиҗаздан кайтып барганда Габдел-Бари ахунд Сарайда кунак булды.*

---

[1] Фәс – Марракеш (Марокко).

[2] Җәзаир – Алжир.

[3] үзләренә кирәк чакта.

[4] Петропавловск – хәзерге Казакъстанның төньягында урнашкан шәһәр, Төньяк Казакъстан өлкәсенең административ үзәге.

[5] ахунд (ахун) – Русиядә аерым төбәктәге яки шәһәрдәге мөселман дин әһелләренең башлыгы. Мәсәлән, Шиһабетдин Мәрҗани, Хәсән-Гата Габәши, Муса Җаруллаһ кебекләр ахун булганнар.

[6] хәлифә – Аллаһ илчесенең (Мөхәммәт пәйгамбәрнең) алмашы буларак мөселман өммәтенең һәм ислам дәүләтенең рухани һәм дөньяви яшәеше белән идарә итүче илбашы.

[7] Сарай-е Һумаюн – хәлифә-солтанның сарае.

*Ахунд җәнабләренә[1] шаһанә[2] бүләкләр биргәннән соң, Русия голәмәләренә[3] ун сандык кадәр дини китаплар бүләк иткән иде. 1871 елда Ирбет ярмаркасында[4] җомга хөтбәсендә Габдел-Бари ахунд Хәлифә хәзрәтләренең[5] олы сәламнәрен мөселманнарга ирештерде, бүләкләрне дә сәүдәгәрләр аркылы голәмәләргә күндерде. Ул җомгада мин дә булган идем.*

*Җәннәт мәкян[6] солтан Габдел-Газиз аурупалыларның мәльгун хәйләләренә карата да нәфрәт хисләре кичерә иде, җирәнә иде. Төркиянең бүленеше мәсьәләсе дә сәяси даирәләрдә бәхәс үзәгендә тора иде. Дарданил[7] дисәләр, авызларыннан сулары ага иде, Бусфур[8] дисәләр, кабып йотkандай итәләр иде. Чит дәүләт мөселманнары белән тиешенчә мөнәсәбәтләргә нигез салу мөмкинлеге дә юк кебек иде».*

Китапны басмага әзерләгәндә Муса әфәнде, Госманлы дәүләте тарихына караган кыйммәтле мәгълүматлар белән бергә, Габдерәшит казыйның Русиядә күргән вакыйгалар турындагы хатирәләренә дә урын биргән. Анда хикәя кыйлынган вакыйгалар реаль тарихи персонажлар, аларның авызыннан чыккан сүзләр ул чордагы атмосфераны тоярга ярдәм итә, чынбарлыкның нинди булуын тирәнрәк аңларга мөмкинлек

---

[1] җәнабләре – бер хөрмәтле, дәрәҗәле кешегә яки аксөякләрдән булган затка олылап мөрәҗәгать иткәндә яки искә алганда кулланыла торган олылау сүзе.

[2] шаһанә – кыйммәтле, затлы.

[3] голәмә – мөселман галимнәр; дин галимнәре.

[4] Ырбир ярмаркасы – Ирбет шәһәрендә елга бер мәртәбә үткәрелә торган һәм революциягә кадәрге Русиядә иң олы ярминкәләрнең берсе. 1630 нчы елларда барлыкка килә. Сәүдә күләме һәм сәрмая (капитал) әйләнеше буенча Мәкәрҗә (Нижгар) ярминкәсеннән кала икенче булган.

[5] Хәлифә хәзрәтләре – биредә бөтендөнья мөселманнарының хәлифәсе булган солтан Габдел-Газиз күздә тотыла.

[6] җәннәт мәкян – урыны оҗмахта булырга лаек булган кеше.

[7] Дарданил – Мәрмәрә диңгезен Урта (Ак) диңгезнең өлеше булган Әгә диңгезе белән тоташтыра торган бугаз.

[8] Бусфур – Мәрмәрә диңгезен Кара диңгез белән тоташтыра торган бугаз.

бирә. Гомумән, бу әсәр, Муса әфәнденең үз сүзләре белән әйткәндә: «*...бөек остаз мөхтәрәм Рәшид әфәнде Ибраһим җәнабләренең хатирәләреннән имля кыйлыныл, «Тарихның онытылмыш сәхифәләре»* исеме белән *бер-бер артлы нәшер кыйлыначак силсиләдән* (ягъни чылбырдан) *беренче халка*», ягъни бәжра була. Ә икенче халка «*Русия мөселманларының ачлык халләрендән дәһшәтле бер хатирә*» исеме белән дөнья күрәсе була. Бу документның бер өлеше югарыда 1922 ел вакыйгаларына караган параграфта китерелде.

Инде «***Коръән кәрим айәт кәримәләренең могъҗиз гыйбарәләренә күрә, Йа́җүҗ***»[1] исемле китапка туктап алыйк.

Бу әсәр Муса әфәнде әле Ленинградта яшәгән вакытта, 1930 елның 31 мартында язылып беткән була. Авторның үз сүзләре белән әйткәндә: «*Кәшгарлык Габдеррахман ахунд Насретдин бәрадәрнең сөальләренә җаваб улмак үзрә язылмыш әсәрләрнең бередер*». Китап ислам гыйлемендә «җавабы булмаган өч мәсьәлә» буларак танылган мәсьәләләрне хәл итү йөзеннән язылып, «*Инсаннарның гакыйдә илаһийәләренә бер назар*» (1911) һәм «*Озын көнләрдә рузә*» (1911) исемле ике китабында бәян ителгән иҗтиһадына барып тоташа. Ул өч мәсьәлә ошбулардыр: 1) көндезләре, төннәре атналар, айлар кадәр дәвам иткән якларда ураза мәсьәләсе; 2) Мәккәдән башка, һәммә җиһәтләре кыйбла була алачак җирнең булуы-булмавы; 3) тәкъдирләренә бәйле рәвештә өч талакның була алуы яки була алмавы мәсьәләсе. Бу мәсьәләләрне хәл иткән чакта Муса әфәнде, аерым алганда, Зөлкарнәен[2] кыйссасына туктала һәм бу зат турында «ислам галимнәренең телләре белән, каләмләре белән уйламастан-үлчәмәстән әйтелгән-язылган сүзләре хакында кызганычларын» бәян итә, «Зөлкарнәенне Искәндәр итеп күрсәтүче тәфсирләрдә тәртипкә салынып язылган коткыларны кире кагу йөзеннән мавыктыргыч һәм кызыклы сурәттә фикерләрен» яза. Әмма андый серле тема-

[1] Муса Җаруллаһ. Коръән кәрим айәт кәримәләренең могъҗиз гыйбарәләренә күрә Йа́җүҗ. Берлин, 1933. 38 б.

[2] Зөлкарнәен (гарәпчәдән: Ике мөгез иясе) – «Кяһеф» («Тау куышы») сүрәсенең 83, 85, 94 нче айәтләрендә искә алынган зат.

лар Коръәндә Зөркарнәйен белән генә чикләнмәгәнгә күрә, Муса әфәнде бу юнәлештә фикерләвен дәвам итеп, Һарут-Марут, Йа́җүҗ-Ма́җүҗ, Әсхаб-е кяһеф кебек персонажларга да кагылырга карар кылып, болай дип яза:

«*Олы әһәмияткә ия булган [әлеге] кыйссалар турында ислам галимнәренең озын һәм кыска бәяннары мине һич тә канәгатьләндерә алмыйлар иде. Аларның акылдан, хикәяләү әдәбеннән, аңлатып бирү кагыйдәләреннән бик ерак торган ул бәяннары минем хәсрәтләремне бары тик арттыралар гына иде. Шәкертлек елларыннан бүгенгә кадәр йөрәгемдә булган кадәр көчле бер җәрәхәт, фикеремдә олы бер аптырау дәвам итә иде <...> Соңгы заманнарда рияэәт*[1]*, әдәп-әхлак, сөйләм мантыйгы, фикъһы, усул-ы фикъһы, фәлсәфә кебек гыйлемнәр өлкәсендә иҗат иткән галимнәрнең каләме белән язылган әсәрләрне, ул әсәрләргә карата язылган шәрехләрне һәм шәрехләргә карата язылган аңлатмаларның барысын да укып чыктым. Өммәтебезне җитәкләүче имамнарның олы иҗтиһадлары нәтиҗәсендә теркәлгән гыйлем хәзинәләрен дә еллар дәвамында укып-өйрәнеп чыктым, аларның фикерләү үзенчәлекләрен аңладым, аңлау дәрәҗәләрен үзләштердем. Боларны башкарып чыкканымнан соң дини әсәрләрдә телгә алынып та, әле һаман да хәл ителмәгән мәсьәләләргә күзем төште. Берсе башка берсен я ачыклау өчен, я кямилләштерү өчен, я тәнкыйть итү йөзеннән хәрәкәт иткән ислам мөҗтәһидләренең төрледән-төрле фикерләренең куәтле нурлары белән ул мәсьәләләрнең кайберләрен чишү юлларына чыгарга булдым. Мәзһәб имамнарының өйрәтүләрен күптөрле мәсьәләләрдә, кайчак, җиренә дә җиткерә алдым. Кайчак, өммәтне җитәкләүче имамнарының иҗмагъларына*[2] *каршы чыга идем. Өммәтне җитәкләүче имамнарының чиксез гыйльми кодрәтләренең йөрәгемдә ныгыган булуы аркасында аларга каршылык күрсәтү минутларында, азмы-күпме,*

---

[1] рийазәт – математика; төгәл фәннәр.

[2] иҗмагъ – фикъһы галимнәренең нинди дә булса шәргый мәсьәлә буенча уртак фикергә килүләре һәм шуның нигезендә кабул ителгән шәригать хөкеме.

*газап та кичерә идем. Мәсәлән: колбиләүчелек кебек, Коръән аятьләрен нәсех кыйлу кебек, дәлилләр китерүнең ысуллары кебек иң зур мәсьәләләрдә өммәтне җитәкләүче имамнарының иҗмагларына каршы чыгуым миңа ул кадәр авыр булмаса да, чагыштырмача тагын да җиңел булган кәффарәт мәсьәләсендә[1] дүрт мәзһәб имамнарының иҗмагъларына «Рузә» сәхифәләрендә каршы чыгуым минем өчен гаять авыр булган иде. Хәтта берничә атна дәвамында йокыларымны да качырган иде. Мин ирешә алган кебек үк шәкертләр дә ирешә алган андый нәтиҗәләргә өммәтне җитәкләүче имамнарның килә алмаулары, аларның бу мәсьәләдәге гафиллекләрен йөрәгем һич кабул итә алмый иде, тәмам булмаслык бер нәрсә дип саный иде. Ул көннәрдәге рухи әхвалемне, фикри әхвалемне «Рузә»дә 84–191 нче сәхифәләрдә бәян иткән идем.*

*Атналарча тәмам аптырау эчендә, көчле рухи интегүләр эчендә калдым. Фикерле идем, зикер кыйла идем. Нәтиҗәдә, вөҗүдемә бер тынлык, йөрәгемә олы бер тынычлык иңде. «(الا بذكر الله تطمئن القلوب)»[2], – дидем: «Иҗтиһадым Аллаһ ризалыгы өчен иде, фикерем ихластан Аллаһ хакына иде. Ни башында, ни ахырында һичбер нәфсани[3], фани бер омтылышым юк иде. Коръән кәрим аять кариманәрен, Шәригъ хәким[4], галәйһи-с-салләт вә-с-сәлам, хәзрәтләренең сөннәт нәбәвияләрен, өммәтне җитәкләүче имамнарының иҗтиһатларын булдыра алганың кадәр өйрәнгәннән соң, синең*

[1] кәффарәт мәсьәләсе – нинди дә булса бер сәбәп аркасында үтәлми калган дини йола яки хөкемне үтәлгәннәр рәтенә кертү өчен каралган махсус чаралар; аерым алганда, кылынган гөнаһ һәм хаталарны бетерүче корбан, сәдәка, ураза кебек гамәлләрне белдерә. Биредә Муса әфәнденең җәйге озын көннәрдә һәм «ак төннәрдә» рамазан уразасын тотуның тиеш булмавы турындагы фәтвасенә бәйле сурәттә тотылмаган ураза өчен кәффарәт кылуның да кирәк булмавы хакындагы шәргый хөкеме (фәтвасе) күздә тотыла.

[2] «Йөрәкләр Аллаһны искә алып тынычланалар ләбаса» (Коръән, 13:28).

[3] нәфсани – нәфес коткысы белән бәйле.

[4] Шәригъ хәким (شارع حكيم) – хикмәт иясе булган шәригатьче, ягъни Мөхәммәт пәйгамбәр.

*ихтыярың калмады. Гөнаһың калмады. Насыйбың, әйтергә теләгәнең ни исә, шуны әйт, шуны яз. Һичбер бәла юк. Фикерең дөрес исә, аны башкаларга да ирештерү фарыздыр. Аның турында әйтү вазифаңдыр. Хата булса, бер башкасы аны дөресләр»,– дип әйткән вөҗданымның сүзенә разый булдым.*

*Шуңа күрә, фикерләрем өммәтне җитәкләүче имамнарның бәяннарына яки иҗмагъларына каршы килсә дә, аларны ирекле сурәттә, ихтирам белән һәрвакыт язып чыгара идем. Гыйлем эстәү юлларында минем әхлакый кагыйдәләрем, гомүмгә каршы чыгуым очракларында мине аклandыручы гозерләрем бу иде. Һаман да шул булып кала».*

Муса әфәнденең бу әсәре гаять кызыклы гына түгел, бик үзенчәлекле дә, чөнки ул исламга кадәр, Коръән иңгәнгә кадәр инде мәгълүм булган язма чыганаклар, тарихи фактлар белән эш итә. Мондый эчтәлекле китап, гомумән, ислам дини әдәбияты традицияләреннән чыгып, аның жанр төрлелеген киңәйтә, җитдиләштерә, төрле нигезсез риваятьләр һәм имеш-мимешләр белән тулган дини әдәбият урынына саллы гыйльми-фәнни хезмәтләр язу мөмкинлеген гәүдәләндерә. Мәсәлән, Муса әфәнде самиләрнең (семитларның) сәмави китаплары турында да тәфсилле мәгълүмат бирә, «Гаһыд гатыйк»ның эчтәлеген бәян итә, Коръәнне дә, әлбәттә, игътибардан читтә калдырмый һәм башка бик күп мәгълүматлар китерә, аларны мифологиягә авышмыйча аек акыл белән анализлау нәтиҗәләре белән таныштыра. Мисал өчен яһүдләрнең китаплары турында язылган бер парча китерәбез: «*Йаһүдләрнең «Гаһед гатыйкъ», «Китаб мөкаддәс» исемнәре белән танылган китаплары: 1)»Тәүрат», 2)»Нәбиййүн» 3)»Мәктубат» исемнәре белән өч төр буларак кабул ителеп, боларның барысына бергә Коръән кәримдә «Әсфар»[1] исеме бирелгән.*

(مَثَلُ الَّذِينَ حُمِّلُوا التَّوْرَاةَ ثُمَّ لَمْ يَحْمِلُوهَا كَمَثَلِ الْحِمَارِ يَحْمِلُ أَسْفَارًا بِئْسَ مَثَلُ الْقَوْمِ الَّذِينَ كَذَّبُوا بِآيَاتِ اللَّهِ وَاللَّهُ لَا يَهْدِي الْقَوْمَ الظَّالِمِينَ)[2]

[1] Әсфар (رافسا) (берлектә: сифер (رفس); «язарга» мәгънәсенә ия булган сәфәра фигыленнән) – язма, китап.

[2] «Тәүратны үтәү белән йөкләндерелгәннәреннән соң аны

*Йаһүдләрнең бөтен гасырларда күктән иңгән китапларына мөнәсәбәтләрен бәян итү эшендә бу айәт кәримә могъҗизалы бер тезмә булып; укый-яза белмәүчеләргә башка укый-яза белмәүчеләрдән, башка милләтләрнең һәрберенә дә үзләреннән расүлләр җибәрүләрен бәян итүче алда килгән өч айәт кәримәдән соң, йаһүдләрнең ишәк өстенә йөкләнмеш китапларына кагылышлы мисал зикер итү аеруча мөһим һәм могъҗизалы бәяндыр.*

*«Әсфар» дип аталган китаплар егерме дүрттер. Муса, галәһйис-салəт вә-с-сәлам, хәзрәтләренә иңгән Тәүрат биш сифердер[1]:*

*1) «**Тәквин**»[2]: Адәмнең яратылуын, Нух, Ибраһим, Исхак, Йагъкуб, Йосыф кебек пәйгамбәрләрнең хәятләрен үз эченә ала.*

*2) «**Хоруҗ**»[3]: Мисырда фиргавенләр кулында бәни Исраилнең әсир булуы, Муса пәйгамбәр тарихы, йаһүдләрнең Мисырдан чыгуы, Синай ярымутравында Муса хәзрәтләренә Тәүратнең иңдерелүенә кагылышлы китап.*

*3) «**Сифер әл-әхбар**», «**Сифер әл-лавиййин**»[4]: гомуми хөкемнәр, һәм дә корбанларга, гаетләренә бәйле булган тәгълимат.*

*4) «**Сифер әл-гадәд**»[5]: бәни Исраилнең чүл сәхраләрендәге хәлләре; Филистыйн хөкүмәтләре белән сугышлары Коръән*

---

үтәмәүчеләр сыртына китаплар йөкләп баручы ишәк кебектер. Аллаһның айәтләрен ялганга чыгарган бу кавемнең хәле илләә дә ямандыр!» (Коръән, 62:5).

[1] Муса пәйгамбәргә иңдерелгән биш сәмави китап (Пятикнижие) гарәпчә Әсфар Муса әл-хәмсә (Мусаның биш китабы) дип атала. Сифер сүзе күплекне белдергән әсфар сүзенең берлек саны шәкеле.

[2] «Тәквин» (تكوين) – урысчасы: «Бытие»; гыйбрани (иврит) телендә: Бе-решит (Башланганда).

[3] «Хуруж» (خروج) – урыс.: «Исход»; ивр.: Шмот (Исемнәр).

[4] «Сифер әл-әхбар» (سفر الاحبار), «Сифер әл-лавийин» (سفر اللاويين) – урыс.: «Левит»; гыйбрани (ивр.): Ва-йикра (Чакырды).

[5] «Сифер әл-гадәд» (سفر العدد) – урыс: «Числа»; гыйбрани (ивр.):

*кәримнең «Маъидә» сүрәсендә (20–26) айәт кәримәләрендә сурәтләнгән.*

*5) «**Сифер әт-тәсния**»[1]: илаhи сүзләр. Коръән кәримдә (وَكَتَبْنَا لَهُ فِي الأَلْوَاحِ مِن كُلِّ شَيْءٍ)[2] дигән айәт кәримәдә бәян ителгән илаhи сүзләрдер. Муса, галәйhи-с-сәләт вә-с-сәлам, хәзрәтләренең бөтен васыятьләрен үзендә туплаган.*

*Бу биш китап Муса хәзрәтләренең «Тәүрат»едер. Җир йөзендә әүвәлге өммәтләргә мәгълүм булган китаплар арасында иң мөhим булган җиhан китабыдыр. Иң борынгы канун китабыдыр. «Сифер әт-тәсния» бөтен «Тәүрат»нең йомгаклау өлешедер. Аның рухыдыр. Йаhүд китаплары арасында үзгәртелүдән азмы-күпме сакланып калган бер китап булса, ул китап «Тәсния» китабыдыр.*

*«Сүрәт әл-Касас»та 43 нче айәт кәримә (وَلَقَدْ آتَيْنَا مُوسَى الْكِتَابَ مِن بَعْدِ مَا أَهْلَكْنَا الْقُرُونَ الْأُولَى بَصَائِرَ لِلنَّاسِ وَهُدًى وَرَحْمَةً لَّعَلَّهُمْ يَتَذَكَّرُونَ)[3] айәт кәримәсе бөтен кешеләр өчен «Тәүрат»ның әhәмияте хакында олы бер шәhадәтдер.*

Моннан тыш, «Йаҗүҗ» китабында Муса әфәнденең бик кызыклы лингвистик карашлары бәян ителә. Шундый бер мисалны түбәндә татар теленә тәрҗемә итеп китерәбез: «*«Тәүрат» сүзе дә, ихтимал, төрки сүздер.*

*Элеккеге өммәтләрнең китаплары арасында, кешеләрнең диннәренә, фикерләренә тәэсир итү җиhәте белән, «Тәүрат» иң борынгы, иң мөhим, иң бөек Җиhан китабыдыр. Коръән кәримдә* (إِنَّا أَنزَلْنَا التَّوْرَاةَ فِيهَا هُدًى وَنُورٌ)[4] кебек, (وَلَقَدْ آتَيْنَا مُوسَى الْكِتَابَ مِن بَعْدِ مَا أَهْلَكْنَا الْقُرُونَ الْأُولَى بَصَائِرَ لِلنَّاسِ وَهُدًى وَرَحْمَةً لَّعَلَّهُمْ يَتَذَكَّرُونَ)[4] *кебек айәт кәримәләрдә «Тәүрат» хакында үтә*

Бе-мидбар (Чүлдә).

[1] «Сифер әт-тәсния» (فسر التثنية) – урыс: «Второзаконие»; гыйбрани (ивр.): Дварим (Сүзләр).

[2] «һәм аның өчен ләүхә такталарда һәрнәрсә турында яздык» (Коръән, 7:145).

[3] «әүвәлге буыннарны һәлякь иткәнебездән соң Без Мусага кешеләргә мәрхәмәт буларак күзләре белән күрерлек тугры юл күрсәтә торган китап бирдек, бәлки алар исләренә төшерерләр» (Коръән, 28:43).

[4] «әүвәлге буыннарны һәлякь иткәнебездән соң Мусага китап

*дә тәэсирле мактаулар иңдерелгән. «Тәүрат»ның асыл теле, бәлки, гыйбранидер[1]. Соңрак арамий һәм сүрьяни телләренә дә, бәлки, күчерелгәндер. Исламнан берничә гасыр элек гарәпчәгә дә тәрҗемә кылынган иде. Насараларның иҗтиһадлары белән бөтен җир йөзенең телләренә дә тәрҗемә кылынды.*

*«Тәүрат» сүзенең асылы йаһүд галимнәренә дә, насара галимнәренә дә әле һаман да мәгълүм була алмаган. Бу сүзнең укылышы, би-л-иттифакъ[2], «тәүрат»тер* (توراة)*. Госманлы дәүләтендә кулланылышта булган мосхәфләрдә[3] язылышы «түрә»дер* (توره)*. Кадим төрекләрме йаһүдләрдән, яки, киресенчә, йаһүдләрме төрекләрдән бу түрә сүзен алганнар? Бу ике ихтималның һәрбере, әлбәттә, мөмкиндер.*

*«Тәүрат» сүзенең тамыры төзелеше дә, һәрхәлдә, әлбәттә, аның алынма сүз булуын күрсәтеп тора. Голүм әдәбия[4] имамнары: тәүрат* (ورى) *тамырыннан ясалган: 1) тәфгаләдер* (تفعله)*, 2) фәүгаләдер* (فوعله) *шәкелендәге, яки* (ت و ر) *тамырыннан ясалган 3) фәгълаттер* (فعلاة) *шәкелендәге сүз, дисәләр дә, мондый сүзләр, әлбәттә, коры бер фараздыр.*

*Фәйләсүф Әбү әл-Галә хәзрәтләре «әл-Лүзүмият»тә күпсанлы сәхифәләрдә бөек хакыйкатьләрне бәян юлында «Тәүрат» сүзенең килеп чыгышы хакында да латыйфәләр[5] әйтеп калдырган:*

(يا آل يعقوب ما توراتكم نبأ من ورى زند ولكن ورى اكباد)
(ان كان لم يبد للاغمار سركم فانه لى فى اكنافه بادى)
(لقد اكلتم بامر كله كذب على تقادم ازمان وآباد)
(ورابنى ان احباراً لكم رسخوا فى العلم ليسوا على حال بعباد)[6]

---

бирдек» (Коръән, 28:43).

[1] гыйбрани – борынгы яһүд теленә караган.

[2] бил-иттифакъ – уртак карашка күрә.

[3] мосхәфләр – Коръән кәримнең кулдан язылган нөсхәләре.

[4] голүм әдәбия – гуманитар фәннәр, аерым алганда филология, тел белеме.

[5] латыйфә – үткен мәгънәле.

[6] Гарәпчәдән тәрҗемәсе: Әй, Йагкуб угыллары! Бу сезнең Тәүратегезнең чакмагы (чакматашы) түгел, / бары тик бавырларны

*Бөек фәйләсуфнең бу әйткәннәре сүзнең килеп чыгышы хакында, әдәп имамнарының*[1] *сүзләре кебек матур, әмма коры бер фараз гына исә дә, «Гаһед гатыйкъ»ның эчтәлекләре хакында, әлбәттә, тугрыдыр.*

(عليك العقل فافعل مارآه جميلا فهو مشتار الشوار)

(ولاتقبل من التوراة حكيما فان الحق عنها فى التوارى)

(ارى اسفارها ليهود اضحت بوارى قدحسبن من البوار)[2]

*«Бория* (بوريا) *сүзе бәвардән*[3]*, Тәурат – тәварадән*[4] *ясалган» дигән сүз гайәт гүзәл бер латыйфә исә дә, «Тәүрат» сәхифәләре яһүдләргә бория* (بوريا) *булды, хак һәм хакыйкать «Тәүрат»тән тәмам мөтавари*[5] *иде» дигән сүз һәрвакыт дөрес иде, бүген тагын да ачык хакыйкать булды.*

*Түрә* (توره)*,* Torah *сүзенең асылы «Гаһед гатыйкъ» белгечләренә дә мәгълүм түгел икән, Тәүрат кәлимәсе хакында әдәп имамнарының иштикаклары*[6] *да коры бер фараз икән, бу очракта, «түрә» сүзе, һәрхәлдә, төркидер*[7]*. Аның канун,*

---

яндырган бер хәбәрдән башкасы түгел // Шәядь җаһилләр сезнең серегезгә вакыйф булмаса да / ул үз өртүләре астында минем өчен ачыктан ачыктыр // Борынгыдан бирле ялган чаралар белән / кешеләрнең малларын даимән ашап тордыгыз // Сезнең тирән белем ияләре булган галимнәрегезнең / һичбер вакыт гыйбадәт кылучылардан булмавы мине шөбһәгә төшерде.

[1] әдәп имамнары – биредә филология белгечләре күздә тотыла.

[2] Гарәпчәдән тәрҗемәсе: Акылыңны уйлап файдалан! Аның яхшы күргәнен кыйл, чөнки ул сатып алучыдыр // Тәүраттән һичбер хөкемне кабул итмә, чөнки чынбарлык аннан яшерелгән // Яһүдиләрнең китапларын «бурьядән» чыккан дип уйлыйм. Хәлбуки, әлегә кадәр ул «бәвар» сүзеннән килеп чыккан дип уйланылды.

[3] бәвар (بوار) – сүзлектә бу сүз үлү, юкка чыгу, нәтиҗәсез булу, файдалана алмау мәгънәләренә ия.

[4] тәвара (توارى) – яшеренергә, качып ятарга.

[5] мөтәвари (متوارى) – яшеренүче, качып ятучы.

[6] иштикак – сүзнең килеп чыгышын өйрәнә торган фән; этимология.

[7] Татар теленең аңлатмалы сүзлегенә (Казан, 1981) күрә, түрә сүзенә түбәндәге мәгънәләр хас: 1. Эш башында торган кеше, башлык; 2. Гореф-гадәт, йола, тормыш кагыйдәләре; 3. Суд, хөкем; 4. Хаким (ягъни судья).

*карар, хаким кебек күптөрле мәгънәләре бар. Гарәп сүзе булса иде, гыйбрани сүз булса иде, аның башка шәкелләре дә нигезле булыр иде.*

*«Тәурат»* (تورات) *сүзенең асылы «түрә»дер* (توره)*. Аның «Әсфар хәмсә»*[1] *дигән исеме төректән алынган. Госмани мосхәфләрдә*[2] *аның түрә* (توره) *рәвешендә язылышы да безгә дәлил була ала. Зәйд бин Сабит*[3] *кебек ышанычлы кятиб*[4]*, әлбәттә, Коръәннең язылышын уйлап чыгарган кеше түгел, бәлки күчереп язучыдыр. Коръән язылышларының күплегенә, үзгәрешләренә ачык дәлил табылмаганнан соң, «Тәүрат» тәфгалә* (تفعله) *үлчәмендә, яки фәүгалә* (فوعله) *үлчәмендәдер дигән сүзләре буш бер сүз булып кала.*

*Безнең Угыз* (اوغوز) *Ханыбыз, Үгезебез* (اوگوزمز) *Зөлкарнәен булса да, булмаса да, Үгез* (اوگوز) *Түрәсе, һәрхәлдә, йаһүд «Түра»сеннән* (توراسندن) *борынгырактыр. Үгезнең Түрәсе, Чыңгызның Йасасы*[5]*, Тимернең Түзүге* (توزوگی) *– һәммәсе төрек малыдыр. «Түрә» сүзе «төрек»тәндер, яки «төрек»* (تورك) *сүзе «түрә»дәндер. Йаһүднең «Түра»сы төрек «түрә»сеннән алынган.*

---

[1] «Әсфар хәмсә» – Биш китап (урыс.: Пятикнижие).

[2] Госмани мосхәфләр – Госманлы Дәүләти Галийәдә (Бөек Госманлы дәүләте) кулдан язылган Коръәннәр күздә тотыла.

[3] Зәйд бин Сабит (611–665) – Мөхәммәт пәйгамбәрнең сәхабәсе, аның сәркятибе вазифаларын башкарган, пәйгамбәргә Аллаһтан иңдерелеп торган Коръән айәтләрен язып барган. Мөхәммәт пәйгамбәрнең вафатыннан соң, Коръәннең тулы нөсхәсен җыю һәм теркәү белән шөгыльләнгән комиссия әгъзасы булган.

[4] Кятиб – күчереп язучы; секретарь.

[5] Ченгизнең Йасасы – Чыңгыз хан игълан иткән яшәеш, идарә итү, яу чабулар кануннары. Йаса сүзе – «яса» фигыленән ясалган сүз булырга мөмкин, әмма бу – бәхәсле караш, чөнки нәкъ киресе була ала: яса боерык фигыле йаса тарафыннан тыелмаган эшгамәлне белдерергә мөмкин. Моннан тыш, йаса (яса) сүзе канун тарафыннан тыелган нәрсәне белдергән йасак (ясак) сүзенең ясалышында катнаша. Хәзерге төрек телендә йаса сүзе Anayasa (Анайаса) (ягъни Ана Канун, Ана Закон; Конституция) кушма сүзне ясауда кулланылган.

*Тәүрат сүзе белән тур* (طور) *сүзенең дә якын мөнәсәбәтләре күзгә күренеп тора. Гыйбраничеләр мондый бер карашны, әлбәттә, кабул итә алмаячаклар. Тур сүзе йаһүдтә юк. Аларда хуриб* (حوريب) *сүзе бар. Коръән кәримнең төзелешенә, мосхәфләрнең язылышларына әһәмият биргән ислам галимнәре дә мондый бер карашны кабул итә алмаячаклар. Әмма Тәүрат сүзенең асылы «түрә» сүзе булудан башка бер ихтимал юк.*

*Сәер һәм тирән мәгънәле бер сүз:* (اكليل الكرامة فى مسائل الامامه)[1] *исемле китабында Бһупал хакиме нәвваб*[2] *Сиддыйк Хәсән*[3] *хәзрәтләре димеш: «Сәясәт* (سياست) *сүзе Чыңгызның сә*[4] *йасасеннән (ягъни: өч йаса) дан алынган»*[5]*. Сәясәт сүзенең чыганагын, сәясәт сүзенең тамырларын мәгънәләрен бәян кыйлу хосусларында сәер һәм тирән мәгънәле бер бәяндыр. Уйгыр төрекләренең мәгърифәте белән теркәлеп, Каан* (قاآن) *Чыңгыз исеменә тоташтырылган өч йасә* (اوچ یاسه) = *сә йасә* (سه یاسه) = *сийасә* (سياسه) *төрек сүзе, төрек милке булса, «Төрек тарихы һәйъәт җәлиләсе»*[6] *әгъзаларының, хосусан*

[1] «Әклил әл-кирамә фи мәсә’ил әл-имамә» (гарәпчәсе: اكليل الكرامة فى مسائل الامامه) яки (اكليل الكرامة فى تبيان مقاصد الإمامة) – гакыйдә, мәзһәбләр һәм диннәр мәсьәләләренә багышланган китап.

[2] нәвваб – губернатор.

[3] Сиддыйк Хәсән (Сиддыйк Хәсән Хан; 1832–1890) – XIX гасырда Һиндестан мөселман җәмгыятенең танылган әйдәүчесе, Бһопал штатының иң атаклы мөселман галиме булып саналган, хезмәтләрен гарәп, фарсы, урду телләрендә язган, гарәп теле лексикографиясе буенча зур белгеч булган. Табигатенең каршылыклы булуы аның шәхесенә карата каршылыклы бәяләмәләр бирелүгә китерә: кайбер чыганакларда ул радикаль фундаменталист, мәкерле сәясәтче буларак тасвирланган булса, башка чыганакларда Һиндестан мөселманнарының бәйсезлеге өчен барган сәяси көрәшнең күренекле каһарманы буларак сурәтләнә.

[4] сә (фарс.) – өч.

[5] Сиддыйк Хәсән китабыннан китерелгән өземтәнең ахыры чамалап кына бирелә, чөнки М. Бигиевнең китабында өземтәне «тәмамлаучы» куштырнаклар куелмаган.

[6] «Төрек тарихы һәй’әт җәлиләсе» («Олуг Төрек тарихы җәмгыяте»; «Türk Tarih Kurumu») – 1931 елда Төркиядә Мостафа Кәмал

*Төркиянең горурлыгы булган сәйидә Әфәт ханым*[1] *кебек затларның гүзәл чыгышларына өстәлә алачак менә дигән бер дәлилдер»*.

Телгә алынган бу әсәрнең ифрат кызыклы булуын истә тотып, кушымтада татарчага тәрҗемә ителгән 7 һәм 8 бүлекләрен китерәбез[2].

## Хатын-кызга мәдхия

Муса Бигиевнең дин галиме буларак күтәргән һәм хәл итү юлларын тәкъдим иткән иң мөһим мәсьәләләрнең берсе исламияттә хатын-кыз мәсьәләсе һәм аны хәл итү чараларын һәм юлларын табу һәм аларны өммәткә, ислам дине хөкемнәре белән дәлилләнеп, иң нигезле сурәттә тәкъдим итү була. Бу тема аның «***Корьән кәрим айәт кәримәләре нурлары хозурында хатун***»[3] исемле китабында һәрьяклап карала, өйрәнелә, тәфсилләп аңлатыла һәм хәл ителә. Китапның беренче юлларында Муса әфәнде: «*Бу китабымны ислам гаиләләренең һәрберенә ихтирамымны белдерү юлында яздым, язарга көч-кодрәтем җитәрлек булганга түгел иде, бары тик көчле теләгем булганга күрә кулыма каләм алдым. 1916 нчы елның азакларында Петербургта тәмамлаган булсам да, нәшер итү мөмкинлегенә бары тик 1933 нче елда Берлинда ирешә*

---

Ататөрек күрсәтмәсе белән оештырылган фәнни-иҗтимагый институтларның берсе. Әлеге оешма, Аурупа тарих фәнендә төрекләр турында тискәре карашларга җавап бирү йөзеннән, җиһан тарихында төрекләр тарихын борынгы заманнардан ук өйрәнүне, аларның чын урынын күрсәтүне максат итеп тота.

[1] Муса әфәнденең Әфәт ханымны искә алуы Төрек тарих оешмасы ачылуы уңаеннан 1932 елның июль аенда үткәрелгән Беренче төрек тарих конгрессына бәйле.

[2] Карагыз: III Бүлек. 21: «Йа́җүҗ» китабыннан. (Әлеге китап турында язылган бер мәкаләбезне дә укый аласыз: Хайрутдинов А. Г. Междисциплинарное исследование Мусы Бигиева о понятии «йаджудж-маджудж». Minbar. Islamic Studies. 2020; 13(1):117–134. https://www.minbar.su/jour/article/view/723)

[3] Муса Җаруллаһ. Корьән кәрим айәт кәримәләре нурлары хозурында хатун. Берлин, 1933. 112 б.

*алдым*», дип яза да, үзен Ибне Фатыйма, ягъни Фатыйма углы дип атап, әсәрне үзенең тормыш иптәше, сөекле хатыны Әсма-Галия ханыма багышлый:

«*Сәййидәм*[1] *Галиям*[2] *Әсма ханым*

*Изге Коръәндә бәян ителгән*[3] *гаилә төзелешен һәм аның яшәеш тәртипләрен кыскача рәвештә сурәтләү теләге белән, мөселман ханымнарының һәрберенә ихтирам белдерү юлында язылган бу «Хатун» исемле китабымны сиңа,– утыз еллык бөтен мәшәкать вә борчуларымны олы шәфкате*[4] *белән, олы мәрхәмәте белән күтәргән сәййидәмә, бөтен балаларымны, олы гаиләмне бәхет эчендә тәрбия иткән мөктасыйд*[5] *гыйффәтле гомер юлдашыма, сүзе белән, йөзе белән, үзе белән калебемне һәрвакыт шатландырган сәййидәмә, галиямә,– Әсмамә тәкъдим итәм. Гомерлек кимчелекләремне гафу итү йөзеннән әсәремне кабул ит!*

*Гомеремнең азагында бөтен кәримәләремне, угылларымны, рәхимле хөрмәтле аналарын зинданнарның, сөргеннәрнең тетрәндергеч вә хурлыклы газаплары эчендә калдырдым. Гөнаһым юк иде, кадернең*[6] *бер хөкеме булды. Гафу итмәсәң – хакың бар. Ләкин, рөхсәт ит, мөбарәк аякларыңны гөнаһлы йөзем белән үбим*».

Гомумән, горбәтлектә дөнья күргән бу китапта Муса әфәнденең гаиләсе белән аерылышуны бик авыр кичергән булуы чагыла. Китапта мондый сүзләр бар: «*Читтә, ят илләрдә япа-ялгызым сабыр кылып гомер елларымны үткәрәм. Агыладыр айлар. Күр имди: һич тә чыдар хәлләрем калмады!*». Читтә яшәгән еллар дәвамында Муса әфәнде газиз хатыны

---

[1] сәййидә – хатын-кызга ихтирам белдереп дәшү сүзе; бикә.

[2] галия – югарылыкка ирешкән.

[3] бәян итү – сөйләм яки язма телдә нәрсәне дә булса аңлату, ачыклау, төшендерү; хәбәр ителәсе фикерне тыңлаучыга яки укучыга җиткерү.

[4] шәфкать – мәрхәмәт, йомшаклык.

[5] мөктасыйд – булган малны исраф итмичә тотучы; гаилә бюджетын сакчыл сурәттә сарыф итүче.

[6] кадер – язмыш.

илә балаларын большевиклар корган читлектән коткарырга тырышкан булса да, бу эш барып чыкмый.

Китапның башында «гаилә», «хатын», «хатун», «кадын» сүзләренең килеп чыгышы кебек, беренче карашка вак булып күренгән нәрсәләр каралса да, авторның бәяны ул сүзләргә хас булган мәгънәләр, аларга салынган фәлсәфә мәсьәләләренә күчкәч, укучының аңы да, күңеле дә, хисләре дә гыйлем вә хикмәтнең бөтенләй башка, югары катламнарына аша. Алга таба китапта дөнья халыкларының әдәбиятлары үрнәгендә хатын-кызга карата булган мөнәсәбәтләре, төркиләрнең «Дәдәм Коркуд» исемле борынгы дастанында гүзәл затларның, башка милләтләргә нисбәтән, искитәрлек югарылыкка куелуы һәм моның сәбәбе, хатын-кызларга ислам динендә булган ихтирам күрсәтү һәм аны тергезеп, дөньяга мөселманча карашны тиешле урынга урнаштыру, һәм башка бик күп ифрат та әһәмиятле олы мәсьәләләр игътибар үзәгенә куела. Китапта параграфлар саны гына да йөз илледән артык. Бу күпкырлы һәм бихисап мәгънәви катламнарга ия булган әсәр турында, яки, аңа таянып, дин, әхлак, әдәбият, тарих, филология, психология, педагогика, этнология һәм фәннең башка өлкәләре буенча тирән анализга корылган аерым махсус фәнни тикшеренүләр киләчәктә, әлбәттә, языла.

Замандашыбыз, фәлсәфә докторы, ислам фәлсәфәсе белгече Тәүфыйк әфәнде Ибраһимның фикеренчә, исламияттә хатын-кыз мәсьәләсе Муса әфәнде мирасының иң матур, иң күркәм сәхифәсен тәшкил итә. Тәүфыйк әфәнде болай ди: «*Муса Бигиев мөслимәләрне ир-ат дин галимнәре тарафыннан динебезнең ялгыш аңлатылган хөкемнәреннән шул кадәр тырышып яклаган! Бу хакта Муса әфәнде менә нәрсәләр әйтә: Безнең диндә, яһүд, христиан диннәреннән аермалы буларак, хатын-кыз шайтан тозагы буларак сурәтләнми. Корьәндә мондый карашларның эзе дә юк. Безнең диндә җәннәтне ялгышып югалтучы Хәүва түгел, Адәмдер, ә Хәүва хәзрәтләре җәннәтне үзенең иренә тугры калуы аркасында югалта. Адәм Хәүвага ияргәнгә түгел, нәкъ киресе – Хәүва ирен ялгызлыкта калдырмаганга күрә җәннәттән чыга.*

*Димәк, Корьәндә беренче кешеләрнең җәннәттән мәхрүм ителүләренең гаебе тулаем Адәм җилкәсенә ята!*»[1]

Бу әсәрендә Муса әфәнде гомумән ислам дөньясында һәм, аерым алганда, дини китапларда, ислам голәмәсе карашларында ир-атның хатын-кызга карата булган мөнәсәбәтен тәнкыйтьли. Аның фикеренчә, ир-атның күзен һәм калебен күркәм әхлак һәм ихтирам хиҗабы капламыйча, хатын-кызны тукыма астына яшерүнең һәм аның дүрт дивар тоткыны итүнең мәгънәсе юк: «*Исламият хатын-кызның мәчетләрдә, уку йортларында, мәҗлесләрдә ачык йөз илә йөрүенә каршы тормый. Әмма исламият ханым вә туташларның әдәпсезлек, азгынлык кылуларын кискен рәвештә тыя. Бу максатка ул хатын-кызның ирееген чикләү юлы белән түгел, бәрәкәтле үгет-нәсыйхәт юлы белән ирешә. Хатын-кыз белән ир-ат арасында чын мәхәббәт булмыйча, бер-берсенә карата мәрхәмәтле вә тигез мөнәсәбәт булмыйча, ни гаилә, ни куәтле дәүләт, ни сәламәт милләт булмаячагын аңлар вакыт җитте инде*».

Муса әфәнде гаиләне чын мәгънәдә кешечә яшәүнең иң кыйммәтле башлангычы, иң кадерле казанышы итеп таныган. Ул болай дигән: «*ХаЛәкатьнең максаты гаиләви тормыштыр. Гаилә – җәннәткә таба атланыла торган беренче адым. Адәмне җирдә хәлифә итеп торгызганда Аллаһ тәгалә гаилә иминлеге дигән бер генә максатны күздә тоткан. Адәм тулы бербөтеннең яртысы гына. Бары тик хәләл җефете илә бергәлектә ул кямил бербөтенгә әйләнә ала. Хатының булмаганда, ни гаилә юк, ни Аллаһның әмерен үтәү юк, ни җәннәт юк*».

Китабыбызның кушымтасында бу мөбарәк хикмәт чишмәсеннән татар теленә тәрҗемә ителгән парчалар китерәбез[2].

---

[1] Тәүфыйк Ибраһимнан алынган интервьюны Муса Бигиевкә багышланган документаль-нәфис фильмда карагыз: И раскололся месяц… https://www.youtube.com/watch? v=F0ZbFd8UfdQ (23.07.2022 каралды).

[2] Карагыз: III Бүлек. 22: «Хатун» китабыннан.

## Шигыйлар дөньясына сәфәр

1934 елда Муса әфәнде кабат Финляндиядәге дуслары белән күрешә. Биредә яшәгән татарлар әүвәлге Петроград имамнары булган Муса әфәнде белән Лотфулла Исхаковны үзләренең остазлары, имамнары буларак танып, аларны икесен дә бик хөрмәт итә торган булганнар. Бу җәһәттән, фин илендә хәлле тормыш корып яшәп яткан тырыш вә булдыклы диндәш вә милләттәшләренә Муса әфәнде һәрвакыт таяна алган, ә алар исә һичкайчан сынатмаганнар. Гомеренең азагында язган бер хатында Муса әфәнде үзенең Финляндиядәге милләттәшләренә атап, мондый сүзләр әйткән: «*Финляндия мөселманнарының җәннәт кебек ханәләренә, миңа карата күрсәтелгән бик зур сайгы эчендә 7–8 ай кадәр бер вакыт, хөрмәтле бер мосафир идем. Бөек хөрмәтегезне күрмәктә идем. Үзем дә сезгә, һәрберегезгә, сайын ханымнарыгызга, кәримәләрегезгә, әдәпле вә акыллы бөтен балаларыгызга холусы калебтән сайгыларымны җиткерәм.*

*Гаять пакь калеб белән, гаять пакь күз белән, ханәләрегездә, җамигъ вә мәчетләрегездә, мәктәп вә мәҗлесләрегездә булдым. Садыйк тел белән сөйләшә идем. Көндезләре, кичләре, озын көннәрдә әдәпле, хөрмәтле гаиләләрегездә, кәнәфи һәм алачыкларыгызда төнге 12-ләргә кадәр, бәлки озын көннәрдә сәхәр сәгатьләренә кадәр ханәләрегездә, гаиләләр арасында, олы хөрмәт эчендә, сезнең белән сохбәт итә идем. Телем пакь иде. Күзем пакь иде. Калебем тәмамә пакь иде. Миңа сайгыгыз кадәр, яки миңа булган хөрмәтегездән каткат күбрәк мин сезне калебемнән ихтирам итәмен. Бу һәм бүген шулайдыр, һәм дә та кыяматкә кадәр сезгә тәшәккерләр итәмен*».

Финляндиядә Муса әфәнде Иран белән Гыйрак консуллыкларына мөрәҗәгать итеп, шул илләргә барырга виза, ягъни рөхсәт ала. Аның нияте Иранда һәм Гыйракта яшәгән шигый мәзһәбендәге мөселманнарның тормышы белән якыннан танышу була.

Шигыйлар дөньясына сәфәрен Муса әфәнде Гыйрактан башлап җибәрә. Муса әфәнденең бу сәфәре турындагы мәгълүмат аның хатларында сакланган. Гыйрактан язган бер мәктүбендә ул болай дип язган: «*Багдадта [уйлаганымнан] бераз озаккарак калдым. Басрага, Нәҗәфкә сәяхәтләремне кыйлдым. Мәүлет көннәрендә биредә калачакмын. Моны, Багдад галимнәре теләделәр, мин дә кабул иттем. Багдад галимнәре белән бераз таныштым. Кичләрен сохбәтләр башланды. Төрле темаларда сүз сөйләдем. Моннан соң әһәмиятле күпсанлы темаларда, гыйльми, әдәби мәсьәләләрдә сохбәт мәҗлесләре туплана торган булды. Дини, әдәби вә гыйльми мәсьәләләрдә Багдадның зур галимнәре фикерләрен бәян итә торган булдылар.*

*Бу йөздән, тагын беразга калдым. Биредә урыным гаять яхшы. Имам әгъзамның мәчете Багдадның иң матур вә җәннәт кебек төзек урындыр. Имам Әгъзамның гаять төзек кабере белән бүлмәмнең арасы 5–6 метрдан артык түгел. Бүлмәмдә ике айдан артык игътикяф кебек бер хәлдә калып, гаять мөһим китаплар укыдым. Бере – 15 томлык вә һәрбере 450 сәхифә кадәр «Тарихы Багдад» әсәре, икенчесе дә 30 томлы «Мәсбут» [исемле] фикъһы китабыдыр. Имам Әгъзамның мәзһәбендә булган имам Мөхәммәднең бөтен китапларын, Шәмсел-әиммә Сәраһси хәзрәтләренең гаять файдалы әсәрен шәрехе белән берлектә зур бер дикъкать белән укыдым. Файдаландым вә бик мәмнүн булдым. Калебемдә бөек бер хәсрәт бар иде. Һәрникадәр бу әсәрне 1927-дә сатып алган булсам да, Ленинградта аны мөталәга итә алмаган идем. Имам Әгъзамның үзе янында мөталәга итеп, голүм фикъһиямне тулысынча яңадан аруландыру сәгадәте насыйп булды. Моңа сөендем. Багдадта имам Әгъзам янәшәсендә бераз игътикяф иттем. Мәмнүнем. Ничә Багдад галимнәре белән таныштым. Биредә калсам, вазифалар да әзер. Фәкать калырга ниятем юк*»[1].

Муса әфәнденең Багдадтан җибәргән хатларының берсендә мондый сүзләр бар: «*Аңлашыла ки, биредә озакка кала*

[1] Uralgiray. Mektuplar, s.13.

*алмаячакмын. Мосул, Кәркүк, Кәрбәла, Нәҗәф вә Күфә кебек шәһәрләрне гиздем, күрдем. Бик күңелсезләндем. Биредә Кәрбәла, Нәҗәф вә Күфә кебек изге урыннарда ясак урыннарны мөшаһәдә иттем. Ясак көннәр гаҗәеп һәм сәер көннәрдер. Һәр көн күреп торам. Гыйбрәтле, тәәссүфле хәлләре мине нык хәсрәтләндереп изә. Кече-олы бер-ике галимнәре белән очраклы сурәттә күрешеп сохбәт итәмен. Фикерләре чикләнелгән, тәгассыб көчле, шигыйлек вә сөннилек дошманлыгы ахыр чигенә барып җиткән. Мондый әхвәлнең чараларын табу бүген бөтенләй мөмкин булмаган бер нәрсәдер. Нәҗәф сәййидләре, Нәҗәф мөҗтәһидләре боларга каршылык күрсәтү юлында 4–5 китап язып тараткannar. Һәммәсен укыдым. Өммәтнең әүвәлге гасырын, көферләшүдән артык, үз араларында атышулардан башка анда һичбер нәрсә таба алмадым. Шигыйларны Көнбатыш кадерли имеш.* (اصل الشيعة واصولها) *исемле китапны язган мөҗтәһид Мөхәммәд әл-Хөсәйни әл-Кәшиф әл-Гыйта*[1] *горурлану теле белән моны миңа үзе сөйләде. Никадәр зур гафиллек! Көнбатышның кадерләве мондый сурәтләрдә бары тик пассив була ала. Ислам милләтләре арасында дошманлык хисләрен куәтләндерәчәк һәр китап, һәр әсәр, Көнбатыш карашында әлбәттә кабул ителә. 100 сәхифәлек кечкенә генә бу китапның нәкъ 20 сәхифәсе мөтга турындадыр. Укыдым. Бик нык аптырадым. Йа́җүҗ рисаләсе кебек бер брошюра яза алсам, мөтга темаларында халыкның бик күп вәһемнәрен кире кагар идем. Коръән кәримдә мөтга юк. Коръән кәримдә мөтга бар иде, мәнсух ителде дип әйтү дә зур бер гафиллектер. Коръән кәримдә мөтга бар дип әйтү илаһи тел белән әйтелгәннәрдән гаять зур гафиллектер. Китапларымда кечкенә вә зур яңа берничә сүз яздым. Моны да яза алсам, янә яңа бер сүзем булыр иде. Калебем сөенер, йөзем – иншаллаһ – тулысынча нурланыр иде. Нәҗәфнең мәдрәсәләрен гиздем. Бу мәдрәсәләр матәм көннәрендә тулысынча ялдадыр. Дәресләр үткәрелми.*

[1] Мөхәммәд-Хөсәйн Кәшиф Әл-Гыйта (1877–1954) – Бөек аятолла, шәех, шигый мәзһәбендәге фәкыйһ, фәлсәфәче, язучы, мөгаллим.

*Мөхәррәмнең 10 ыннан соң дәресләр башлана. Дәресләрен дә күрдем. Ысул тәмамы белән Бохара мәдрәсәләре ысуллары кебектер. Бераз аңладым аермаларны: мәзһәб башка вә дәрес китаплары да башкадыр. Низам тәмамән Бохара низамыдыр. Мәдрәсәләрнең бинадары Бохарага нисбәтән бераз кечерәк исә дә, һәм тыштан, һәм эчтән тәмамы белән Бохара мәдрәсәләре корылмалары кебектер. Биреләрнең дини әдәбләрен бераз күргәннән соң, Бохара мәдрәсәләренә рәхмәтләр укыдым. Әгәр безнең мәзһәбебез, безнең әдәбебез Багдад вә Нәҗәф кебек җирләрдән алынган булса иде, безнең мәчетләребез дә тәмамән Нәҗәф мәчетләре кебек булыр иде. Безнең дә мәхрам матәмнәребез булыр иде. Мәхрам матәмнәре белән чамасыз сурәттә мавыгулары, намаз фарызларында, пакьлек вазифаларында чамадан тыш игътибарсызлык вә әһәмият бирмәүләре миндә бик яман эз калдырды. Махрәм матәмнәрендә гаять сәер вә чиркандыргыч хәлләрен күрдем. Нәҗәф кечкенә бер шәһәрдер. Һәр көн, һәр төн һәр җирдә, иртә-кич Хөсәен шәһадәте хакында гаҗәеп вә сәер хикәяләр укып еглау вә ләгънәт уку, йөзләренә ору, күкрәкләрен куллары белән кагу кебек хәлләр, әйтерсең, диннең гыйбадәте вә иң саваплы рөкеннәре имеш кебек, балалар, хатыннар, ирләр тарафыннан олы бер әһәмият белән вә бик зур ихлас белән башкарыла. Нәҗәф вә Кәрбәлада 26 көн кадәр калдым. Яңа хәлләр күрдем. Тагын бик күпләрен күрәчәк идем, фәкать майның 5 ендә кире кайттым.*

*Хәзерге урыным Багдадтадыр. Имам Әгъзам Әбу Хәнифә хәзрәтләренең кабере янында бик матур бер җирдәдер.* دار العلوم الأدبية والدنية[1] *мәдрәсәсендә гаять матур бүлмәмдәмен. Мин хәнәфимен. Бу урын имам Әбу Хәнифә раузасыдыр. Калебемдә бирѳдә бераз икамәт итмәк[2] теләге уянды*».

Финляндиягә язып җибәргән бер мәктүбендә Муса әфәнде маҗара фильмы сценариясенең нигезенә ятарлык хатирәлә-

[1] Дару әл-голүми әл-әдәбиййәти вә әд-диниййәти – Әдәби (әхлакый) һәм дини гыйлемнәр университеты.

[2] икамәт итмәк – яшәп торырга; тукталып торырга.

ре белән уртаклашкан. Ул хатны татар теленә тәрҗемә итеп кушымтада бирдек[1].

1934 елның 18 июлендә Муса әфәнде Багдадтан поезд белән көнчыгышка – Иран чигенә таба юлга чыга. Көндәлек язмаларына караганда, дәүләт чиген ул Ханәкыйн шәһәрендәге кизү ноктасы аша уза һәм Иран җиренә аяк басып, Касры-Ширин, Шаһабад (хәзерге вакытта Исламабад-ы Гарыб), Кирмәншаһ, Хәмәдан, Кәзвин кебек шәһәрләр аркылы сәфәр итә. Бу шәһәрләрнең һәммәсендә туктап, берникадәр вакытын үткәреп, шәһәрнең үзе һәм андагы истәлекле тарихи урыннар белән таныша. Муса әфәнде бу сәфәре турында көндәлекләрендә язмалар теркәп барган: «*1934 сәнә июль 28-дә кытарда Багдадтан хәрәкәт итдем. Ногман, Кәмал, әл-Әмин – [барысы] алты-җиде таләбә озатды. Сабах 29-да Ханкыйнда. Халык истикбаль итде. Дар әз-зыяфәдә*[2] *карар итдем*[3]*. Һәммә кибар*[4] *зиярәт итде. Сабах 30 да хәрәкәт итдем. Тәфтиш*[5] *могаянә*[6] *мөгамәләләре Ханәкыйн ходүдендә иҗра кыйлынды*[7]*. Котылдым. Каср-ы Ширин, Байтак, Шаһабадны*[8] *үтдек. Бәгде-зуһыр сәгать дүрт радәләрендә*[9] *Кирмәншаһ шәһәренә ирешдек. Кундык. Шәһәрне тамаша итдем. Хәрап бер шәһәрдер. Хаммамнары, әҗзаханәләре*[10]*, саъилләре*[11]*, фәкыйрьләре гаять чук шәрык шәһәредер. Базар фәкыйрь иде. Шәһәр таглар арасындадыр. Июль 30 да һавасы могтәдил*[12] *иде. Большәвикләрнең биредә бераз әсәрлә-*

[1] Карагыз: III Бүлек. 23: Финляндиягә язган хатларыннан.

[2] дар әз-зыяфә – кунакханә.

[3] карар итдем – урнаштым.

[4] кибар – танылган атаклы шәхесләр (түрәләр, галим-голяма һ.б.).

[5] тәфтиш – тикшерү (таможняда).

[6] могаянә – паспорт (документ) тикшерелә торган урын.

[7] иҗра кыйлынды – башкарылды.

[8] хәзерге вакытта Исламабад-ы гарб исемле шәһәр.

[9] радәләрендә – тирәләрендә.

[10] аҗзәханә – даруханә, аптека.

[11] саъил – теләнче.

[12] могтәдил – уртача.

*ре бар. Кирмәншаһта бер төн кундым. Иртән сәгать җиде радәләрендә хәрәкәт итдем. Юлда алты сәгать кадәр хәрәкәттән соң, Хәмәдан шәһәренә ирешдек. Әбу Гали Сина каберен зиярәт итдем. Исеменә бер кыйраәтханәсе*[1] *дә бар. Бер сәгать кадәр истирахәттән*[2] *соң хәрәкәт итдек. Акшам сәгать сикез радәләрендә Казвин шәһәренә ирешдек. Бер төн биредә кундык.*

*Иртән алты радәләрендә иде, хәрәкәт итдек. Әйлүл*[3] *бер иде, сентябрь бер иде. Юлда могаянә һәр җирдә. Сәгать 10 радәләрендә шәһри Тәһран шәһәренә якынлашдык. Берничә җирдә полис безне туктатты. Гакыйбәт*[4]*, Тәһран шәһәренә дахил улдык*[5]*. Палас Һотелдә 14 нумарада җирләшдем.*

*1934 сәнә сентябрь бер. Тәһранның хариҗи*[6] *җиһәтләрен бераз күрдем. Почталары, банклары, телеграфханәләре гүзәлдер. Рус әшьялары базарларында тәмам мәбзүлдер*[7]*. Һәрҗирдә рус хуруфаты*[8]*, ничүндер, бардыр.*

*Хатун бурада гаять мәбзүл*[9] *имеш. Бөек шаригларда*[10] *фәхишәләр тулыдыр. Тәгаҗҗеб итдем*[11]*.*

*Аугустус 5-дә күчә-и*[12] *Басырида нумара 3-дә бүлмә алдым. Җиде туман җитмеш кыйран айлык. Гыйракның динары, инглизнең фунты биредә сиксән кыйран»*[13]*.*

Борынгы фарсы илендә Муса әфәнде җирле халыкның тормышы белән якыннан, араларында йөреп таныша, дини

---

[1] кыйраәтханә – уку бүлмәсе.

[2] истирахәт – ял.

[3] әйлүл (төрек.) – сентябрь.

[4] гакыйбәт – ниһаять, ахыр чиктә, соңыннан.

[5] дахил улдык – кердек.

[6] хариҗи – тышкы.

[7] мәбзүл – күп, мул; тулган.

[8] хуруфат – хәрефләр, язулар.

[9] мәбзүл – җиңел табыла торган; арзан.

[10] бөек шаригъларда – зур урамнарда.

[11] тәгаҗҗеб итдем – гаҗәпләндем, аптырадым.

[12] күчә – урам.

[13] Муса Җаруллаһның куен дәфтәре. Төркия Милли китапханәсе. A3851–4. Б.4–5.

мөназараларда катнаша, мәдрәсә мөгаллим вә шәкертләре белән күрешә, китапханәләрдә эзләнүләр үткәрә. Шигыйлар күпләп яшәгән Гыйракта башланган сәфәрен Иранда дәвам иткән Муса әфәнде, шул рәвешле, ислам диненең шигыйларча ничек тотылуын өйрәнә, ниятендә инде туган яңа гыйльми хезмәтенә материал вә мәгълүмат туплый. Сәфәре дәвамында Муса әфәнде үзенең Финляндиядәге дуслары белән дә арасын өзми, мөмкин булганда хатлар язып тора. Шундый хатларның берсендә галим Иран турындагы күзәтүләрен, тәэссөратларын бәян итә: «*Шираз Иранның җәннәт кебек бер урыны икән, ләкин Финляндиядәгеләргә күрә түгел. Иран авылларында газап эчендә, авыр хезмәт вә мәшәкать белән яшәгән кешеләр хакында Иран шагыйрьләренең сүзләре бәлки тугрыдыр да. Сез, мөхтәрәм Финляндия мөселманнары, дөньягызда вә динегездә шат булып бәхетегезнең кадерен белегез*».

Ирандагы Мәшһәд шәһәреннән язган хатында, олуг шагыйрь Фирдәүсинең каберен күргәннән соң, тәэсирләнеп, Муса әфәнде мондый сүзләр язган: «*Мәшһәдтә Фирдәүсинең каберен зиярәт иттем һәм сөендем. Фирдәүсинең кабере дөньяда гадәттә 7 гаҗәибтән саналган мавзолей шәкелендәдер, гаять матурдыр. Москвадагы Ленинның төрбәсеннән дә кат-кат газаматлыдыр. Тәмамән буш бер җирдә исә дә кабернең әйләнә-тирәсенә бик зур гөлбакча һәм бакча ясалган. «Шаһнамә» мөәллифе Фирдәүсинең 1000 еллык юбилее хатирәсенә Шаһ Риза-хан Пәһләви тырышлыгы белән төзелгән. Шаһ бүген мәдәният дөньясында, бөтен йир йөзендә, бу бөек шагыйрьнең хөрмәтенә аның юбилеен үткәртте*».

Муса әфәнденең мәктүпләре һәм көндәлекләрендәге язмалар ул кылган сәфәрләрнең георафиясен төгәл күзалларга мөмкинлек бирә. Мәсәлән, Иранннан язган бер хатында ил буенча кайдан кая таба, кайчан, ничек һәм нинди шартларда хәрәкәт итүләре бәян ителә: «*Тәһраннан 19 ноябрьдә акшам сәгать 5-ләрдә Тәбризгә хәрәкәт иттем. Кар, яңгыр һәм давыллы җил аркасында һава торышы бик начар иде. Сәяхәтебездән бераз элек бик хаста булсам да, калебем ни булса да, шат вә күтәренке иде. Автобус юлда бер мәртәбә*

*чокырга төште һәм капланды. Бер тапкыр автобус эчендәге бензин багынга ут кабып, тәмам ике бак бензин янып автобусның эче кып-кызыл рус миче кебек тулысынча утка әйләнде. Ут ишек яныннан яна башланды. Кешеләр автобусның тәрәзәләрен ватып берәр-берәр тышка атылдылар. Кешеләрнең паникага тотылулары куркыныч иде. Мин ничектер мондый каплану минутларында да, янгын минутларында да мөвазәнәмне[1] бозмадым, акыл салкынлыгын да югалтмадым. Иң соңа калып тәрәзәдән иплән кенә чыктым. Бензин яна, кешеләр ыңгырашалар, мин тамаша итеп тора идем. Шуннан соң төнлә Кум шәһәренә барып җитә алдык. Пычрак изеп йөри торгач, көч-хәл белән бер урын таптым. Бүлмә никадәр салкын булса да, йокыга киттем. Иртән исән хәлдә уяндым; 1) Тәһрандагы хасталыгым; 2) кар, яңгыр йә һава бозыклыгы; 3) каплану һәм яну тәһликәләре[2] аркасында бөтен гәүдәм кыйналган сыман иде. Шулай да шәһәр урамнарына чыгып бераз йөрдем. Шәһәрнең иң мәшһүр зиярәт урыннарын, мәчетләрен һәм мәктәпләрен гиздем. Иң бөек мөҗтәһидләренең бөек дәресләрендә булдым. Бер мөҗтәһиднең өендә кечкенә генә бер мәҗлестә ике-өч сәгать кадәр сохбәттә катнаштык. Мин сөйләдем, алар тыңладылар. Бүген сыйххәтем бераз яхшырак. Бераз йөреп кердем. Соңгы сыйныф укучылары белән уку бүлмәләрендә бераз сөйләшеп утырдым. Биредә бәлки бер атна кадәр калырмын*».

Күренгәнчә, Муса әфәнденең хатларында сәфәр маҗаралары гына түгел, аның шәхси сыйфатлары чагыла. Мәсәлән, Ираннан җибәргән хатларының берсендә ул, имам Вәли-Әхмәт әфәнде хәзрәтләренә булса кирәк, мондый бер тәкъдим ясый: «*Һелсинкидә (фәлан) әфәнде хәзрәтләренә тәшәккер вә миннәтләремне[3] шөкер һәм рәхмәтләремне кабат белдерсә-*

---

[1] мөвазәнә – тигезлектә булу; аек акыллы булу; паникага бирелмәү.

[2] тәһликә – каза, авария; һәлакәт, яшәү өчен куркыныч булган вакыйга яки хәл.

[3] тәшәккер вә миннәтләремне – шөкер һәм яхшылыгынын кадерен белүләремне.

*гез һәм үзен ише белән берлектә өегезгә дәгъвәт итсәгез яхшы булыр иде. Дәгъвәтегезне әлбәттә кабул итәрләр. Сезнең рәсми хәлегез гаять яхшыдыр. Үрнәкне Шәрыктән түгел, Гаребтән алыгыз*».

Мусә әфәнденең Гыйрак белән Ирандагы сәфәре, бер елдан артык дәвам итеп, 1935 елда тәмамлана. Бу чын мәгънәдә, галимнәр теле белән әйткәндә, «кырда» үткәрелгән фәнни тикшеренү экспедициясенең никадәр әһәмиятле булуын аның үтә дә нәфис образлар телендә әйтелгән түбәндәге сүзләреннән аңларга мөмкин: «*Минем карашларымның почмаклары ачылып китте һәм уйларымның нурлары тәнасеб [симметрия] үзәге өстендә урын алдылар*».

## Яңадан Мисырда

1935 елның азагында, шигыйлар дөньясы белән танышу сәфәрен тәмамлап, Муса әфәнде Каһирәгә юл тота. Биредә сәфәр дәвамында җыелган материалларын тәртипкә китерә, шуңа таянып, гарәп телендә, даны бөтен ислам дөньясына таралган мәшһүр «***Әл-Вәшигату фи нәкъди гакаъиди әш-шигати***»[1] («Шигыйчыларның инанулары тукымасын сүтү шүресе») исемле (шулай ук «***Әл-Вәшига***» дип аталган) хезмәтен яза һәм аны Каһирәдә бастыра. Бу әсәр ислам дөньясында, беренче нәүбәттә шигый голәмәсе арасында кайтаваз уята, китап турында Гыйрак, Иран, Мисыр матбугатында хәбәрләр чыга. Гарәп илләрендә аның бу әсәре, узган XX гасыр дәвамында берничә мәртәбә нәшер ителеп, безгә мәгълүм булган басмалары 80 нче елларда дөнья күрә. 2002 елда әсәр, рус теленә тәрҗемә ителеп, Казанда «Иман» нәшриятында басылып чыга[2].

---

[1] Муса Җаруллаһ. Әл-Вәшигату фи нәкъди гакаъиди әш-шигати. Каһира: Матбагату әл-Канҗи, 1935. 238 с.

[2] Карагыз: Муса Джарулла (Бигиев). Критика шиитских воззрений. Аль-вашиа фи накд акаид аш-шиа. Челнок для раскрутки пряжи воззрений шиа. Казань: Издательство «Иман», 2002. 160 с. / Перевод с арабского – Шагавиев С. А.

Муса әфәнде үзе «***Әл-Вәшига***»ны шигыйларга каршы язылган хезмәт буларак күзалламаган: «*Минем китабым шигыйларны кире кагу түгел, ә кирәкле җаваптыр. Аның сәхифәләрендә файдалары зур булган хәерле нәсихәтләр күп. Әгәр аның уннан бер өлеше шигайчыларга юл күрсәтү өчен язылган булса, калган тугыз өлеше – мөһим мәсьәләләрне хәл итү өчен язылды*»[1].

Әмма Иран хөкүмәте шушы китабы өчен Муса Җаруллаһка илгә керүне рәсми рәвештә тыя. Бу – кызып китеп, үч алу йөзеннән эшләнгән эш булып тора. Бераз вакыт узгач, Иранның югары катлам идарәчеләре даирәсендә Муса әфәнденең китабына мөнәсәбәт үзгәрә булса кирәк, чөнки 30 нчы еллар ахырында Иран хөкүмәтенең кайбер сәхабәләргә бәддогалар укуны тыю турында фәрман чыгаралар.

Финляндиягә язган хатларының берсендә бу китабын искә алып, Муса әфәнде болай дигән: «*Кулыгызда минем «әл-Вәшига» китабым бар. 210–211 нче сәхифәләрендә ураза айәт кәримәләре хакында минем иҗтиһадым бар. Ачык яздым. Дүрт мәзһәбнең һичберсендә юк исә дә Коръән кәримдә бар. Әһле исламның һәрберенә ураза фарыздыр. Хәйретдин Гали, Гыймад Җәмал, Зуһур Таһир һәм Исмәгыйль Гариф кебек затларның һәрберенә итгам фарыздыр. Һәр көн итгам, фитыр сәдакасы кебек һәр көн сәдака. Нәби мөхтәрәм хәзрәтләренең бөтен сәхабәләрен, Имам Әгъзам кебек мөҗтәһидләрнең гаять мөстәхәб сөннәтләре, мохтаҗ гаиләләргә, фәкыйрь хатыннарга, фәкыйрь кешеләргә хөрмәт кулы белән тәкъдим кылыначак бер һәдия исламиядер. Гаять гүзәл бу сөннәтебезне бүген Финляндия гаиләләре өчен дә ихъйа кылыгыз. Рамазан кичләрендә тәравихтан соң һәр кемсә үз аулагында шатланып сәхәрен ашасын. Коръән кәримнең голүвиятле иршады сезгә бүген менә будыр. «Әл-Вәшига»мны яздым. Гыйрак тупракларында керүен Гыйрак хөкүмәте, ачыктан-ачык ясаклады. Зарары юк, мин вазифамны башкардым. Әһәмияте бик зур булган берничә мәүзугда иҗтиһадымны ислам га-*

---

[1] Battal-Taymas A. Sovyetler Diyarında Görüp Geçirdiklerim. Tasvir, 17 Ağustos 1948. S. 21. (Чыганак: Kanlıdere. Күрс. хезм., б. 126).

*лимнәренә гарыз иттем. Китабым шигыйларга рәддия түгел, кирәкле бер дәгъвәттер. Файдасы бик зур булган яхшы бер нәсихәттер. Китапның уннан бере шигыйларга нәсихәт юлында исә, калганы мөһим мәсьәләләрне хәл итү юлында язылган. Әйтелергә тиешле берничә фикерем бар иде, аларны әйттем. Калебем бераз рәхәтләнде. Өммелмөэминин Гаишә, Хафса кебек әһле бәйт хакында, ислам имамнары Әбу Бәкер Сиддыйк һәм Гомәр әл-Фарук кебек дин нигезләре хакында вазифамны аз булса да башкардым. Шигыйларның хәтерләренә ригаять белән ислам хөкүмәтләре тыйсалар, ә ислам галимнәре дәшми калсалар, бу миңа янә дә олы бер шәрәфтер.*

***Сезгә ачыктан-ачык әйтәм: «Әл-Вәшига»дагы мәсьәләләрне ислам фәкыйһларына тәхәдди рәвешендә яздым. Кодрәтләре бар исә, сүзләремне тәмамы белән рәдд итсеннәр. Хаталарымны кабул итеп, гөнаһларымны һәркемнән элек таныйм**. Ләкин минем хаталарым – ислам өммәтенең шәрәфедер. Әүвәлге иске дәгъваларым да хәтеремдәдер. Раст була алсалар минем йөзем кызармас. Исламның йөзе нурланыр. **Минем киң хөрриятем, халисанә бик тирән ихтирам нигезләренә таяна**. Әүвәлге иң беренче китабым «Таъриху әл-Куръәни вә әл-мәсахифи» иде. Мөгаен, иң соң китабым да Коръән кәрим хакында, Мәсахиф кәримә хакында булачактыр. 35 ел эчендә нигезле мөһим мәгълүмат тупладым. «Гакыйдәтел-үммати фил-Коръән әл-кәрим вәлмәсахиф әл-кәримә» исемле бер китап нәшер итүне бисмиллаһ дип башладым. Вафатымнан соң ислам балаларының кулларында бер ядкәр булыр».*

## Китапларын гарәп телендә язу. Артур Җеффери

Муса әфәнденең эмиграция дәверендә китапларын гарәп телендә язуына да туктап алыйк. Аның болай итүе, беренче карашка, табигый бер хәл булып күренә, чөнки ислам дөньясында гарәп теле дин галимнәре, укымышлы мөселманнар даирәсендә гомуми төс алган халыкара аралашу-аңлашу теле булып торган һәм хәзерге көндә дә шул хәлдә кала бирә. Әмма Каһирәдән язган мәктүпләренең берсендә Муса әфәнденең

гарәп телендә яза башлавының сәбәбе тагын да тирәнрәк ачыла: «*Зарлану түгел, бу бер хикәядер. Төрекчә никадәр китап яздым исә – исраф булды, аяныч, тулысынча иһмаль кыйлынды*[1]. *Шуның өчен бераз хәсрәттәмен. Булдыра алсам, ике-өч китабымны гарәпчә нәшер итәчәкмен иншаллаһ*».

Каһирәдә чагында Муса әфәнде үзене дини-гыйльми эзләнүләрен, шул исәптән Коръәнгә, аның тарихына багышланган тикшеренүләрен дәвам иттерә. Хатларының берсендә галим болай ди: «*Мин китапханәдә иртәнге сәгать 9 дан өйләдән соң сәгать 5 кә кадәр эшлим. Бик күп китап укыдым. Калебем бу яктан бераз сөенечледер. Әүвәлге йөзьелларда язылган хәзрәти Госман мосхәфләренең биредә иң борынгы бер нөсхәсе бар. Идарәдән рөхсәт алдым. Бүген һәм киләчәк көннәрдә моны баштан ахырына кадәр укып, мөһим табышлар чыгарачакмын. Кәлимәләрен, сүрәләрен, айәтләрен, язу ысулларын, әнәр булса – истисналарын*[2] *тәмамән язармын иншаллаһ. Коръән турында бик күп әсәр укыдым*».

Мөмкинлектән файдаланып Муса әфәнде Мисырдагы гомуми вазгыять, дини гыйлем учакларының хәле, уку-укыту эшләренең куелышы белән якыннан таныша. Каһирәдән язган мәктүпләренең берсендә ул болай дигән: «*«Әл-Әзһәр» әүвәлге хәлендәдер. Укучылар азайган. Дәресләренә бер күз аттым. Низам әүвәлге хәлендә исә дә, әүвәлге остазларның сайгылары вә белемнәре бүгенге мөгаллимнәрдә калмаган булуын аңладым. Бер остаз белән бер шәкертнең бер-берсен көфер итеп сугышканнарын күрдем. Моңа соң дәрәҗәдә мөтәәссир булдым. Дәресләрен бераз тыңладым. Безнең фәкыйһләрнең фикерләре, кызганыч, бик кысыр, гаять караңгы. Кайгым бик артты. Төркестан вә Төркия мәдрәсәләренең башларына яуганнарның бер көн әл-Әзһәрнең дә башына киләчәге мохакъкактыр*[3] *һәм якындыр.*

---

[1] иһмаль кыйлынды – игътибарга алынмады, санга сугылмады.

[2] истисна – искәрмә, чыгарма; кагыйдәгә яки гадәткә туры килмәгән нәрсә.

[3] мохакъкак – катгый рәвештә чынбарлыкка аша торган.

*Шәрык мәдрәсәләренең тәрбияләре шәрык балаларының миләренә тудыру куәте бирә алмады. Ислам фәкыйһләренең бөтен башлары тәмамән кысыр булып калган эшләре, тулы мәгънәдә биремсез[1] булды».*

Каһирәдә үткәргән айлар дәвамында Муса әфәнде Мисырның танылган шәхесләре – яшь чагында дуслашып өлгергәннәре белән дә, яңа танышкан дин галимнәре, фән эшлеклеләре һәм язучылар белән аралаша. Андыйлар арасында ислам тарихының беренче дәвере турында язучы тарихчы Әхмәд әфәнде Әмин, Коръән тәфсире авторы, «Әл-Әзһәр» университетының әүвәлге ректоры шәех Мостафа әл-Морагый, Каһирә мәгариф бүлеге дәүләт инспекторы Гали Габдерразикъ-паша, фән докторлары Мансур Фәһми белән Габделваһһаб Газзам һәм башка күренекле затлар була. Бу даирәләрдә гыйльми моназаралар, фикер алышулар – еш күренеш, Муса әфәнде янында үзенә күрә интеллектуаль бер түгәрәк оеша. Аның белән аралашучылар арасында Аурупа галимнәре, Шәрыкны өйрәнүче белгечләр, дин әһелләре дә була. Шундый танышларының берсе турында Муса әфәнде мәктүпләренең берсендә болай ди: «*«Таъриху әл-Куръәни вә әл-мәсахифи» исеме белән биредә бер әсәремне нәшер итәчәк булдым. Кыйммәтле мәгълүмат тупладым. Гомеремнең ахырында янә мөһим бер китабымны нәшер итәргә телим. Тәкъдирдә шаян бер хәлдер. Биредә эшләгән бер инглиз миссионеры 15–20 ел кадәр гомерен багышлап Коръән кәримнең шазз[2] кыйраәтләрен зур игътибар белән җыйган. Минем белән дә шул эше аркылы танышты. Миннән күп файда алды. Бөтен эшләрен аңладым. Үзенә гаять әһәмиятле мәгълүматлар бирдем. Никадәр олы галим исә дә миннән иң югары дәрәҗәдә кыйммәтле билгеләр алды. Аның эшеннән хәйран калдым. Гаҗәп. Христианнар Коръән кәрим хакында иҗтиһад кыйлалар. Ислам галимнәре исә моны тәмамы белән ташладылар. Каным кайнады, көнләштем. Соңгы бер әсәремне нәшер итим, дидем».*

---

[1] биремсез – нәтиҗәсез, буш.

[2] шазз – сирәк очрый торган.

Бу хатта сүз Австралияле шәркыятьче галим Артур Җефери[1] турында бара. 1936 елда Каһирәдә Җеффери үзенең 1937 елда чыккан «*Materials for the History of the Text of the Qur'an: The Old Codices*» («Коръән тексты тарихы өчен материаллар: борынгы мосхәфләр») исемле хезмәтенә кереш сүзе яза. Анда ул Муса әфәндегә шөкерләрен белдереп, мондый сүзләр әйткән[2]: «*My special thanks are due to two Oriental savants, Musa Jarullah Rostovdani of Kazan and Shaikh Sayyid Nawwar of Cairo, both of whom have read with me all the shadhdh qira'at from the Old Codices and taught me many things that a Christian can hardly learn for himself*».

Ягъни: «*Казанлы Муса Җаруллаһ Ростовдони белән Каһирәле Шәех Сәгыйд Нәүвәр атлы ике шәрык галименә минем махсус шөкерләрем: аларның икесе минем белән борынгы мосхәфләрдән сирәк очрый торган (шазз) кыйраәтләрне укыр иделәр һәм миңа бер христианның үзлегеннән өйрәнә алмаслык күп нәрсәләрне өйрәттеләр*».

Җефферигә гыйльми ярдәм күрсәтән чакта, күңелендә уянган ниятен тормышка ашырыр өчен, Муса әфәнде шул ук мәктүбендә Финляндиядәге дусларына мөрәҗәгать итеп, болай дип яза: «*Беренче әсәрем, «Таъриху әл-Куръәни вә әл-мәсахифи». Бу беренче әсәремне күрим. Зинһар, бик тиз шул китабымны миңа җибәрегез. Хәтта башка китаплар белән бергә бер арага тупланган булса, алардан аерып миңа почталагыз. Хәлем бик таркау. Бәлки дә гомерем ахырына җиткәндер. Коръән гыйлемнәре хакында Аурупа вә Америка*

[1] Артур Җеффери (1892–1959) – австралияле ислам белгече, 1921 елдан Каһирә Шәрык белеме мәктәбендә (хәзерге вакытта Каһирә Америка университеты) сәми телләре профессоры, 1938 елдан вафатына кадәр Колумбия университетында профессор. Коръән буенча берничә җитди фәнни тикшеренү авторы. «Коръәннең әҗнәби сүзлеге» исемле әсәрендә Изге китапта гарәп теленә башка телләрдән үтеп кергән 318 атама барлыгын раслаган.

[2] Jeffery A. Materials for the History of the Text of the Qur'an: The Old Codices. Leiden: E. J. Brill. 1937. 630 p. (карагыз: https://archive.org/details/in.ernet.dli.2015.76212/page/n7/mode/2up

*галимнәренең могаззам[1] иҗтиһадларын күреп калебемдә бик зур тәъәссерләр уянды, йөрәгемдә зур бер дулкынлану бар.* (وَإِن تَتَوَلَّوْا يَسْتَبْدِلْ قَوْمًا غَيْرَكُمْ ثُمَّ لَا يَكُونُوا أَمْثَالَكُمْ)[2] *[айәтенә күрә] ислам җиңеп килер, заһир булыр, бөтен җир йөзенә җәелер. Фәкать безнең кулыбыз белән һәм безнең тырышлыгыбыз белән түгел, башка милләтләрнең кулында үзенең бөек вәгъдәсен чынбарлыкка ашырыр өчен Аллаһ җәллә җәлалүһу башка колларын тапты.* (يَسْتَبْدِلْ قَوْمًا غَيْرَكُمْ ثُمَّ لَا يَكُونُوا أَمْثَالَكُمْ)[3] *айәтенең мәгънәсе дә бу имеш».*

Шул ук 1935 елда Каһирәдә ул гарәп телендә язылып исламның төрле проблемаларына багышланган берничә китабын бастыра. Андыйлардан:

«***Низаму әт-тәкъвими фи әл-ислами***»[4] («Исламда календарь тәртибе»);

«***Низаму ән-нәсьйи гыйндә әл-гарәби каблә әл-ислами***»[5] («Исламга кадәр гарәпләрдә елларны оныттыру тәртибе»);

«***Таърихху әт-тәшригы әл-исламийи***»[6] («Ислами кануннарның барлыкка китерелеше тарихы»);

«***Әййаму хәйати ән-нәбийи әл-кәрими саллә Аллаһу галәйһи вә сәлләмә***»[7] («Бөек пәйгамбәр, саллә Аллаһу галәйһи вә сәллам тормышының истәлекле көннәре»);

---

[1] могаззам – бик зур, бөек, олы.

[2] «әгәр Аллаһның әмерләреннән йөз чөерсәгез, Ул сезнең урынга башка бер кавемне китерер һәм алар сезнең кебек булмаслар» (Коръән, 47:38).

[3] «Ул сезнең урынга башка бер кавемне китерер һәм алар сезнең кебек булмаслар» (Коръән, 47:38).

[4] Ибн Фатыйма. Низаму әт-тәкъвими фи әл-ислами. Каһира: Матбагат әс-сәгадәти, 1935. 28 с.

[5] Ибн Фатыйма. Низаму ән-нәсьйи гыйндә әл-гарәби каблә әл-ислами. Каһира: Матбагат әс-сәгадәти, 1935.

[6] Ибн Фатыйма. Таърихху әт-тәшригы әл-исламийи. Каһира: Матбагат әс-сәгадәти, 1935.

[7] Ибн Фатыйма. Әййаму хәйатт ән-нәбийи әл-кәрими саллә Аллаһу галәйһи вә сәлләмә. Каһира: Матбагат әс-сәгадәти, 1935.

«***Усулу әл-фикъһи вә мәнабигу-һу***»[1] («Фикъһының тамырлары һәм аларның чыганаклары»);

«***Мәсахифу әл-әмсари***»[2] («Башкалаларның мосхәфләре»);

«***Низаму әл-җамигыйати әл-исламийати***»[3] («Ислам җәмгыятенең төзелеше»);

«***Тәфсиру әл-хуруфи әл-мукаттагати***»[4] («“Киселгән хәрефләр”нең тәфсире»);

«***Ли-ма игътабара әш-шәргу әр-руъйата***»[5] («Шәригать нидән яңа туган ай күренүен игътибарга алган?»);

«***Китабу әл-хуҗҗати***»[6] («Хөҗҗатләр (Дәлилләр) турындагы китап»). Бу әсәр Ибраһим Мостафаның Әбу әл-Галә әл-Фарисинең «*Китабу әл-хуҗҗати*» исемле китабына «*Ән-Нукуду галә тәфасыйли әл-гокуди китаби ихъйаъи ән-нәху*» («Нәхүне терелтү китабы»ның төеннәрен тәфсилләп аңлату өчен тәңкә акчалар») исемле тәнкыйди күзәтү рәвешендә язылган китабыннан ясалган чыгарма.

Бу китапларның һәммәсен Муса әфәнде Ибн Фатыйма исеме белән имзалап, шул рәвешле әнисенә карата булган хөрмәтен вә шөкерләрен белдерә. Гарәп дөньясы өчен бер язучының үзен әнисе исеме белән атавы, әлбәттә, бик сәер булып күренә торган хәл. Әмма болай итүе белән Муса әфәнде мөселманнар игътибарын кабат хатын-кызларның, аналарның иң нык ихтирам вә хөрмәт ителгән затлар булырга тиешлегенә җәлеп итәргә, мөгаен, тырышкан.

---

[1] Ибн Фатыйма. Усулу әл-фикъһи вә мәнабигу-һу. Каһира: Матбагат әс-сәгадәти, 1935.

[2] Ибн Фатыйма. Мәсахифу әл-әмсари. Каһира: Матбагат әс-сәгадәти, 1935.

[3] Ибн Фатыйма. Низаму әл-җамигыйати әл-исламийати. Каһира: Матбагат әс-сәгадәти, 1935.

[4] Ибн Фатыйма. Тәфсиру әл-хуруфи әл-мукаттагати. Каһира: Матбагат әс-сәгадәти, 1935.

[5] Ибн Фатыйма. Ли-ма игътабара әш-шәргу әр-руъйата. Каһира: Матбагат әс-сәгадәти, 1935.

[6] Ибн Фатыйма. Китабу әл-хуҗҗати. Каһира: Матбагат әс-сәгадәти, 1935.

Югарыда искә алынган «*Низаму әт-тәкъвими фи әл-ислами*» исемле әсәре турында Муса әфәнде хатларының берсендә мондый сүзләр язган: «*Нәбиләрнең, бөек хикмәт ияләренең юлларына тумыштан ук юнәлдерелгән сәййиде-әнбия Мөхәммәд галәйһис-саләтү вәс-сәлам хәзрәтләре шәгъбан 20дә Җәбәлен-нур мәгарәсенә кереп рамазанның ахырына кадәр шунда игътикяф иткән. Әлбәттә уразалы булган. Кырык көн игътикяфы соңында* (اقْرَأْ بِاسْمِ رَبِّكَ الَّذِي خَلَقَ خَلَقَ الْإِنسَانَ مِنْ عَلَقٍ)[1] *айәт кәримәләре иңгән. Бу соң дәрәҗә бөек, һәм дә бөтен кешелек дөньясына аталган тугры юлга чыгаручы бер вакыйга галәмәт буларак рамазан бәйрәме, гомуми шигарь*[2] *буларак, Мәдинәдә һиҗрәтнең икенче елында карар ителеп изгеләштерелде. Мәккәне яулап алудан соң һәм Дәүләт исламия корылганнан соң бөтен галәме исламның берлегенә шигарь буларак Корбан бәйрәме унынчы зөлхиҗҗәдә игълан ителде.*

*Бу кыска бәянымны* (نظام التقويم فى الاسلام)[3] *да язган идем. Фәкать моңа игътибар иткәннәр аз иде. Бәйрәмнәребез гомуми ислами шигарьләрдәндер. Рамазан бәйрәмебез Коръән иңүенең истәлегедер. Икенче бәйрәмебез исә ислам берлеге шигаредер. Кыйблабыз һәм намазларыбыз да бу берләшүнең гаять нык һәм хакимлек итүче шигарьләредер*».

Алга таба шул ук мәктүбендә Муса әфәнде, үзенең дини гыйлем даирәсендәге эшчәнлегенең кайбер үзенчәлекләренә аңлатма биреп, өммәткә хезмәтенең моңсу нәтиҗәләре турындагы фикерләре белән уртаклаша: «*Мәзһәбләр никадәр*

---

[1] «Барлыкка китергән шул Раббыңның исеме белән укы! Ул инсанны кан куерыгыннан барлыкка китерде». (Коръән, 96: 1–2). Инсан сүзен кеше дип тәрҗемә итү гадәткә кергән, әмма сүзнең тамыры онытырга дигән фигыльдән гыйбарәт булганга күрә, инсан сүзен онытучы / оныткан дип тәрҗемә итү дөресрәк. Ягъни, бу дөньяга кеше гәүдәсендә китерелгәч, Раббыларына биргән антларын (Коръән, 7:172) оныткан әрвахлар күздә тотыла.

[2] шигарь – әйдәмә; лозунг.

[3] «Низам әт-тәкъвим фи-л-ислам», ягъни «Исламда календарь тәртибе».

*аерымланган, никадәр каршылыклы, никадәр кәйфи*[1] *исәләр дә, кыйбла берлегенә, Коръән кәрим гыйсмәтенә*[2] *һәм намаз берлегенә зыян китермәгәннәр. Намазда Коръән кәримнең айәт кәримәләреннән башка һичбер нәрсәнең тилавәт кылынмавының хикмәте дә шушында ята.*

*Фикъһы мәзһәбләренә һәм кәлямчы фиркаларына көчле һөҗүмнәрем дә асылда бу сәбәпләрдәндер. Әсәрләремдә, хәтта, кодрәтемнән ашкан сүзләр белән акырып-чакырып язган булсам, боларның һәрбере дингә булган ихлас куәтем аркасында эшләнде. Һәр сүземдә исламиятнең йөзенә җәмал*[3] *булачак бер мәгънә бар. Моны халык аңламады. Мин исә аңлатудан гаҗиз идем. Кодрәт һәм куәтем юк иде. Җәһаләтем*[4] *дә зур иде. Һичбер заман ислам диненә кимчелек бирәчәк, ислам милләтләренә зарар бирә алачак бер сүз дә әйтмәдем. Бу яктан калебем канәгать һәм рухым мөстәрихтер»*[5].

Мәктүпләренең берсендә Муса әфәнде 1931–1935 елларында күргәннәрен җөпләп, йомгаклап куйгандай, болай дип язган: «*Хиҗаз, Сүрия, Кодес*[6] *вә Мисыр гарәпләрен күрдем. Мәдәни, дини хәлләреннән тәмамән канәгать күрә алмадым. Хәтерегездәдер, Финляндия мөселманнарына сөйләгән идем. Озын сәяхәт авырлыкларын мин күтәрәм, әмма бу авырлыкларның файдалары сезгәдер. Мәмләкәтегезгә, әхвәлегезгә шөкер кыйлыгыз. Финляндиянең кадерен белегез. Рәхәтен күрегез. Ул сүземне Әфганстан вә Һиндестан сәяхәтемнән соң әйткән идем. Хиҗаз, Кодес, Сүрия вә Мисыр сәяхәтләремнән соң янә артыгы белән теләдем. Әдәпнең, пакьлекнең вә мәдәниятнең сездә булуы ягыннан мәмләкәтегез биреләр белән чагыштырганда бик югарыдыр. Кадерен белегез. Финляндия мөселманнарының хәлләре тәмамы белән башкадыр. Финляндия мәмләкәтенең кадерен белеп, үз арагызда гаять дустанә*

[1] кәйфи – берәүнең кәефенә корылган, ихтыяри.
[2] гыйсмәт – пакьлек, арулык; дөреслек.
[3] җәмал – матурлык, гүзәллек.
[4] җәһаләт – җаһиллек; белемсезлек.
[5] мөстәрих – тыныч.
[6] кодес (гарәп.: әл-Кудс) – Иерусалим шәһәре.

*яшәгез. Фин мәктәпләрен тәмамы белән тутырганнан соң, ислам мәктәпләрен дә, дин курсларын да, килеп-китеп укыта торган укытучыларыгыздан да [белемне] һәрзаман бөтен куәтегез белән алып алга атлагыз. Мөселманнарның бүген иң куәтле колониясе – Җәмәгат-е Финляндия мөселманнарыдыр. Мин [Аурупада] (фәлан) шәһәрне, (фәлан) әфәнделәрне вә якыннарын күрдем. Анда дини әхвәлләр бөтенләй башкадыр. Анда тәравих кебек, ураза кебек нәрсәләрнең һичберсе юк. Балаларда уку-язу кайгысы да юк. Мәктәпләрен якында тәмамлаячак булган ике яшь кыз күрдем. Һичберенең мөселманча язудан хәбәре юк. Аталарының аларны кайгыртулары да аздыр. (Фәлан) шәһәрне күрдем. Анда да хәлләр шундый. Ураза юк. Намазлары вә бәйрәмнәре дә юк. Мөфти бар һәм гаять фәкыйрь бер авыл мәчете кебек кечкенә, кысынкы бер мәчетләре вә каберстаннары бар. Ләкин бәйрәм намазлары юк. Сезнең хәлегез бөтенләй башкадыр*».

## Яңадан Һиндестанда

1936 елда Муса әфәнде Мисырдан Һиндестанга китә, Бомбәй (хәзерге Мумбаи) шәһәренә кереп чыга, аннары һиндлыларның изге каласы Бинарискә юл тота. Бу шәһәрдә Муса әфәнде ике айлап вакытын үткәреп, аны бөтенләй ят мәдәниятне һәм динне өйрәнүгә багышлый: «*Мин Бинаристә һинд браһманнарының иң бөек галимнәре хозурында сабак ала башлаган бер шәкерт сыйфатында Һиндның борынгы Ведаларын, Һинд пәйгамбәрләренең күктән иңгән китапларын, Һинд философларының фәлсәфәләрен, хикмәтләрен, тәмамы белән булмаса да, бераз өйрәним дидем, хезмәтем ли вәҗһи Аллаһ*[1] *булыр. Бу гайрәтләрем Коръән кәрим юлында нәби Мөхәммәднең ризасына ирешү максаты белән булыр иншаллаһ.*

(تركت للناس دنياهم ودينهم * شغلا بحبك يا دينى ودنياى)[2]

---

[1] ли вәҗһи Аллаһ – Аллаһ ризалыгы өчен.

[2] Йә динем вә дөньям! Сине яратуым белән шөгыльләнеп, кешеләргә калдырдым дөньяларын да, диннәрен дә. Мансур әл-Халлаҗ (858–922) иҗатыннан.

*Санскрит дин вә фәлсәфәләрен өйрәнү теләге белән Бинариста озаккарак калдым. Моннан соң Җава, Суматра һәм Япония тарафларына сәяхәт итү кирәклегенең үңенә кичелмәс теләге калебемдә куәтләнде. Бисмиллаһи вә мөтәвәккилән галә Аллаһи*[1] *март ахырларында Каликут юллары белән Җава тарафларына иншаллаһ, юнәлермен*».

Ул арада аңа «*Әл-Вәшига*» исемле китабының Һиндестан галимнәре тарафыннан урду теленә тәрҗемә иттереләчәге турында хәбәр ирешә. Бу шатлыклы хәбәрне ишеткәч, ул мондый сүзләр язган: «*«Әл-Вәшига» китабымның кайбер фасылларын Һинд галимнәре урду теленә тәрҗемә иттерәчәкләр имеш. Моңа шатландым. Иран хөкүмәтенең дә сәхабәләргә ләгънәт уку кебек көферлекне тыйганын ишеттем. Монысына аеруча сөендем. Бу, әлбәттә, «Әл-Вәшига»ның тәэсиредер. Минем 1) Зәкят, 2) Рузә, 3) Шәригать әсасләре, 4) Хатун, 5) Мөраҗәгать, 6) Ислам милләтләренә, 7) Кавагыйд фикъһийә, 8) Өммел-кура кебек әсәрләрем, Фин мөселманнарының кулларында барысы туплап, һәрбереннән берәр-икешәр данә миңа бирегә, Бинаристәге адресыма җибәрә алсагыз, файдалы бер эш булыр иде. Анда әһәмиятләре калмады. Бирегә аларны сораучылар бар*».

Бинаристән язган бер мәктүбендә остаз болай дигән: «*Өметләремнең тормышка ашмавыннан кичергән хәсрәт аркасында калебемдә янган бер ут, мине кайгырткан бер газап бар. Бәлки дә каберемнең сәгатьләре якындыр. Алай булса да, соңгы сулышыма кадәр хәрәкәт итим. Егерме кадәр кечкенә һәм 4–5 кадәр зур әсәрем бар. Гомеремнең дәвамлылыгы билгеле булса иде, боларны кичектереп торыр идем дә рәхәт кенә яшәр идем. Бүген үк үлеп китү ихтималларына күрә, һәрберен бүген үк бастыру борчулары үземне дә, калебемне дә гаять рәхәтсез кылып тора*».

Бинаристән Муса әфәнде Һиндестанның башкаласы Дәһлигә бара. Гаҗәп, ят җирләрдә йөрү, юл мәшәкатләре Муса әфәндене һич тә гыйльми эшчәнлегеннән аермый. Бу аның

[1] мөтәвәккилән галә Аллаһи – Аллаһка тәвәккәлләп; Аллаһка тапшырып.

Һиндестаннан язган хатларыннан сизелеп тора: «*Күчүк Мөхәммәт Хәмди*[1] *хәзрәтләренең Коръән тәрҗемәсе вә тәфсире 4–5 ел элек яңа хәрефләр белән басылган иде. Бүген, әлбәттә, тәмамлангандыр. Матбуг бер-ике җилден үзенең кулында, үзенең өендә күргән идем. Байтак сәхифәләрен үзе миңа укыр иде. Охшаттым. Мөгаен, бу иң дөрес тәрҗемә булса кирәк. Сездән үтенәмен, бу тәрҗемә әсәренең басылган бөтен томнарын минем исемемә җибәрегез. Сезгә бик мәшәкать булса да, бу үтенечемне бушка алмыйча, кичектермичә һәм тиз арада үтәсәгез, минем күңелемне күргән булырсыз. Төркиядә күп кешеләр Коръән кәримне тәрҗемә иттеләр. Һәрберен күрдем. Һичбере берни түгел, киресенчә – лә шәйдер*[2]*, һичбер шәйдер. Мәхмәт Хәмди әфәнденең дә тәрҗемә вә тәфсирен күрим. Зинһар, җибәрегез*».

Дөресен әйткәндә, Һиндестан җирләрен төрки канлы татар кешесе өчен ят дип атау дөрес булмас иде, чөнки 1206 елдан 1555 елга кадәр бу ил Дәһли солтанаты дип аталган бик зур төрки империя буларак яши. Солтанатка нигез салган Котыбетдин Айбәкнең нәсел дәвамчылары Һиндестанда ислам динен, әдәп-әхлагын, архитектурасын тараталар. 16 гасырда Дәһли солтанаты зәгыйфьләнә һәм вак солтанлыкларга бүленеп таркала. Шул чакта бу җирләрне Мәвараэннәһердә, Себер, Казан, Касыйм вә Әстерхан ханлыкларында хакимлек иткән Чыңгыз хан нәселеннән чыккан Шәйбаниләр токымының вәкиле Заһиретдин Бабур хан яулап ала да тарих фәнендә Бөек могуллар империясе буларак танылган дәүләт төзи. Шулай итеп, Һиндестанда бер төрки дәүләт урынына икенче төрки дәүләт барлыкка килә. Бабур төзегән дәүләт 1720 нче еллардан башлап зәгыйфьләнә бара һәм 1858 елда инглизләр һөҗүменә чыдый алмыйча юкка чыга. Аның урынында төрки

[1] Күчүк Мөхәммәт Хәмди (Әлмалылы Мөхәммәд Хәмди Йазыр; 1878–1942) – күренекле дин галиме, «Хак дине Коръән теле» исеме белән төрек телендә латин язуында нәшер ителгән тәфсир авторы. Бу тәфсирнең тугыз томы 1935–1939 елларда Истанбулда Диния нәзарәте исәбенә 10000 данә итеп баслып чыга.

[2] Лә шәйъ – һичнәрсә, бернәрсә дә түгел; юк нәрсә.

канлы солтаннар тарафыннан идарә ителгән берничә солтанлык барлыкка килә, әмма алар Бөекбританиягә буйсынулы колонияләр хәлендә булалар. Бу җәһәттән, Муса әфәндебез Һиндестанны ислам иле буларак кына түгел, мөгаен, төркиләр иле итеп тә таныгандыр. Гомумән, Гыйрак вә Сүриядә күргән газаплары булсын, Ирандагы кичергән хәтәр маҗаралары булсын, Мисыр китапханәләрендә эшләп утырган вакыты булсын, кояш нурында коенган Һиндестанда изге китаплар, борынгы тел өйрәнеп яшәгән көннәре булсын – Муса әфәндедәнең көнделекләрендә гаиләсе, дус-ишләре турында хатирәләр һич тә сүрелмәгән. Хатларының берсендә ул мондый сүзләр язган: «*Хатларымны язганда бөтен Һелсинки, бөтен Финляндия гаиләләрен, чынбарлыкта күргән кебек, һәрберен хыял күзе белән күреп-барлап чыгам. Һәрберенә догаларым, һәрберенә сәламнәрем, һәрберенә тәшәккерләремне белдерегез. Юлда күрсәгез, телефонда сөйләшсәгез, мәктүп язсагыз – һәрвакыт сәламнәремне ирештерегез*».

## Япониягә сәяхәт

1938 елда Муса әфәнде Япониядән хат ала. Хатны язучы совет властеннан качып киткән күренекле җәмәгать эшлеклесе Габделхәй Корбангалиев[1] Муса әфәндене Токиода «Исламия» исемле Җәмигъ мәчет ачылышы тантанасында катнашырга дәгъвәт итә.

Ул чакта Корбангалиев белән Габдерәшит казый Ибраһим җирле татар-башкорт мөһаҗирләрен һәм ислам динен

[1] Габделхәй Корбангалиев (1889–1972) – татар-башкорт мөһаҗирлегенең күренекле вәкиле, имам, мөгаллим, җәмәгать эшлеклесе, тарихчы галим. Гражданнар сугышы дәверендә, башкорт гаскәре җыеп, Колчак тарафында большевикларга каршы көрәшә. 1920 елда гаскәре белән Манҗүриягә качып китә, шунда имамлык һәм мөдәррислек итә. 1924 елда Япониягә күчеп, анда «Токио мәхәлләсе» исемле мөселман җәмгыяте оештыра. 1927 елда Япония мөселманнары өчен мәктәп ача, 1928 дә Бөтен Япония мөселман корылтае үткәрә, типография ачып, гарәп һәм татар телләрендә китаплар бастыра, Урал-Алтай халыклары һәм аларның тарихлары турында берничә фәнни хезмәт яза.

кабул иткән японнарны берләштереп, киң колачлы иҗтимагый эшчәнлек башкаралар. Габдерәшит хәзрәт Ибраһим яңа гына тәэсис ителгән Диния нәзарәтенең рәисе итеп билгеләнә, моннан тыш, ул Япония хөкүмәте тарафыннан илдә исламга кагылышлы эшләрне алып бару өчен оештылырган «Dai Nippon Kaikyō Kyōkai» (Япония Олуг Ислам Берләшмәсе) исемле рәсми оешманың да рәисе була. Корбангалиев Япония Диния нәзарәтенең 1924 елда ачылган «Исламия Токио» исемле иң актив бүлекчәләренең берсен җитәкли[1].

Япония башкаласы Токиода Җәмигъ мәчете ачылуы, әлбәттә, татар мөһаҗирлеге тарихында гына түгел, гомумән бөтендөнья мөселман өммәте вә ислам дине тарихы өчен зур һәм истәлекле вакыйга була. Шуңа күрә бу тантананы оештыру зурдан башкарыла, күп кунаклар чакырыла. Токиода Җәмигъ мәчете төзелешен үз өстенә алган Япониянең Олуг Ислам Берләшмәсе ачылыш тантанасына кунаклар чакыру вазифасын нәкъ менә Корбангалигә йөкләгән була[2].

Муса әфәнде бу шатлыклы вакыйгага чакыруны кабул итә һәм диңгез юлы белән юлга чыга. Мәчет ачылышы тантанасы 1938 елның 12 маенда үткәрелә. Әмма Йокоһама диңгез лиманында[3] пароходтан төшеп Япония җиренә аяк баскан мәлдә Муса Җаруллаһны каршылаучылар арасында Габделхәй Корбангали инде булмый, чөнки берничә көн алдан аны кулга алалар, ә 1938 елның июнь аенда ул Япониядән сөрелә[4].

Япониягә барышлый Муса әфәнде хәзерге вакытта Малайзиягә караган, ә Муса әфәнде дәверендә Бөекбритания-

[1] Адутов Р. М. Татарская эмиграция в Японии. http://tatarica.narod.ru/cult/library/book/japan/6_yaponie.htm (23.05.2019 мөрәҗәгать ителде).

[2] Usmanova, Larisa. The Türk-Tatar Diaspora In The Northeast Asia. Transformation of Consciousness: A Historical and Sociological Account Between 1898 and the 1950s. Tokyo: Rakudahsa. P. 102.

[3] Yeşil, Yaşar. Musa Carullah'ın Japonya Seyahati ve Toshihiko İzutsu ile İlişkisi. https://www.dunyabizim.com/portre/musa-carullahin-japonya-seyahati-ve-toshihiko-izutsu-ile-iliskisi-h26827.html (26.05.2019 мөрәҗәгать ителде).

[4] Usmanova, L. Күрсәтелгән хезмәт, p. 102.

нең колониясе булган Порт-Пинанг шәһәрен зиярәт итә һәм андагы китапханәләрнең берсендә сакланган кызыклы борынгы бер мосхәфкә юлыга. Бу турыда ул болай дип яза: «*Бу арада Банки Портпинә шәһәре китапханәсендә шигыйларга кагылышлы булып, нөзүл тарихы үзрә тәртип ителгән бер мосхәфкә дә очраклы рәвештә* [тап булдым] *һәм моны да тәдкыйкъ итмеш идем. Бу мосхәфтә «Маъидә» сүрәсеннән соң «Нурайн»*[1] *сүрәсе белән «Вилаять» сүрәсе исемле ике сүрә кушылган. Фәкать боларның Коръән телен белмәгән бер җаһил тарафыннан уйдырылган булуы бәсбәлли* [билгеле] *иде. Шигыйларның бу шазз* [кагыйдәгә туры килми торган] *хәрәкәтләр белән һичбер бәйләнешләре булмавын сөйләүләре бу өстәмәләрнең һичбер кыйммәте булмавын ап-ачык күрсәтә*»[2].

Күргәнебезчә, кайда гына булса да, Муса әфәнде җай чыккан саен үзенең дини-гыйльми тикшеренүләрен, бу очракта Коръәнгә һәм аның тарихына кагылышлы эзләнүләрен өзмәгән. Малакка бугазы ярларында урнашкан бу шәһәрдә пароходтан төшеп, вакытын вә җаен табып, җирле гыйлем үзәкләрен айкап чыга, кулына кергән һәр кирәкле чыганак һәм документны өйрәнә, аның турында куен дәфтәрләрендә эш нәтиҗәләрен теркәп куя. Галим тапкан мосхәф тә гаять кызыклы булып чыга: 114 сүрә урынына 116 сүрәле Коръән китабы! Галим биредә никадәр әдәпле хәрәкәт итә, күрегез: «Шигыйлар фәлан икән, шигыйлар төгән икән, хәтта Коръәнне дә үзгәртүдән тартынып тормаганнар!» – дип сөрән салмый ул, киресенчә, шигый голәмәсенең мондый «артык сүрәләрне» үз эченә алган мосхәфне дөрес китап дип таны-

---

[1] «Нурайн» (ике нур) – кайбер шигый мосхәфләрендә Коръәнгә кушылган ике өстәмә сүрәнең берсе. Ике нур дигәндә хәзрәти Гали белән аның углы Хөсәен күздә тотыла. Шигыйларның инануларына күрә, Мөхәммәт пәйгамбәрнең вафатыннан соң хакимият һәм хилафәт белән идарә аның гаиләсе әгъзаларына калырга тиеш булган, ягъни башта хәзрәти Галигә, аннан соң – аның углы хәзрәти Хөсәенгә.

[2] Musa Cârullah. Surelerin nüzul tarihi itibariyle tertibi. Yeni Selâmet. C. IV, Sayı 19–87. 18 мая 1949. S. 4, 16.

мауларын ассызыклый, өстәвенә ул кушылган ике «сүрәгә» гарәп теле, Коръән теле белгече буларак тәнкыйди бәя бирә, дөресрәк итеп әйткәндә, аларның ниндидер наданнар тарафыннан уйлап чыгарылган булуын фаш итә.

## Муса әфәнденең шәкерте Тошихико Изутсу

Токиода мәчет ачылышы тантанасы үтеп киткәннән соң, Муса әфәнде белән Габдерәшит хәзрәтләре җирле татар җәмәгатьчелегенә дин сабагы бирү, аны тирәнтен аңлату, җәмгыять тормышын исламча кору алымнарын өйрәтү белән шөгыльләнәләр. Җирлекне Габдерәшит Ибраһим инде әзерләп куйган була, чөнки аның эшчәнлеге нәтиҗәсендә Япониядә төп халык вәкилләреннән һәм, өстәвенә, 5–6 меңгә якын татар мөһаҗирләреннән гыйбарәт булган мөселман җәмгыяте оешып өлгергән була.

Япониягә килеп җитүе белән Муса Җаруллаһ Токио мәчетендә имамлык вазифаларын башкара, мәчет каршындагы татар мәдрәсәсендә дин сабагы укыта[1]. Биредә олуг галимебез белән Тошихико Изутсу[2] исемле бер япон егете таныша[3]. Тошихико гарәп теле буенча сабакны моннан бер-ике ел элек Габдерәшит Ибраһимнан инде ала башлаган була, ислам динен кабул итә. Көннәрдә бер көнне Габдерәшит хәзрәттән: «Мин ислам динен кабул иттем икән, яшәешемдәге нинди нәрсәләрдән ваз кичәргә тиешмен?» – дип сорый. Габдерәшит хәзрәт: «Ашыкма! Ислам синең калебеңә кергәч, дөрес булмаган нәрсәләр синең тормышыңнан үзләре юкка чыгачаклар»,– дип җавап бирә. Остазның гыйлем бирү методикасы аерым игътибарга лаек: ул Тошихикога гарәп телен исламнан аерым хәлдә өйрәнүнең бер ахмаклык булуын аңлатып, аны

[1] Kanlıdere A. Kadimle Cedit Arasında Musa Cârullah. Hayatı/Eserleri/Fikirleri. İstanbul: Dergâh Yayınları, 2005. S. 128.

[2] Кара: İbrahim Kalın. Toshihiko Izutsu. https://islamansiklopedisi.org.tr/izutsu-toshihiko (каралды: 22.05.2019).

[3] Тошихико Изутсу (1914–1993) турында тулырак мәгълүмат өчен кара: Хайрутдинов А.Г. Тошихико Идзуцу: японский ученик татарских устазов. https://islam-today.ru/blogi/ajdar_xajrutdinov/tosihiko-idzucu-aponskij-ucenik-tatarskih-ustazov/

ислам тәгълиматы нигезендә, ислам нигезләре белән бергәлектә өйрәнергә тәкъдим итә. Дәресләрнең берсендә остазы аңа болай ди: «*Сиңа өйрәтә алган һәрнәрсәне өйрәттем. Башка өйрәтәчәк нәрсәм калмады. Әмма минем оныгым булганыңа күрә, монда көн саен килеп йөри аласың. Аеруча, тиздән Япониягә минем белән чагыштырылмаслык дәрәҗәдә зур бер галим киләчәк. Шул ук вакытта, ул тиңдәше булмаган академик та. Сине аның белән таныштырачакмын. Белемне аннан өйрәнә алачаксың*»[1].

Шулай итеп, Тошихико сабырсызлык белән Муса Җаруллаһ әфәндене көтеп ала, остаз Япониягә килеп төшкәч, аның шәкерте буларак тәрбияләнеп, ислам дине нигезләрен, гарәп телен, әдәбиятын, ислам фәлсәфәсен өйрәнә башлый. Әлеге яшь галимнең инде 1941 елда ук Токиода дөнья күргән «*Arabica shisôshi*» («Гарәп фикере тарихы») исемле фәнни хезмәте, һәм, мөгаен, башкалары да, һичшиксез, Муса Җаруллаһ белән якыннан аралашуы һәм аннан ислами белем алуы нәтиҗәсендә язылган әсәрләр булса, гаҗәп түгел. Тошихико Изутсуның Муса әфәнде турында калдырган истәлекләре олуг галимебезнең шәхси сыйфатларын сурәтләүләре белән гаять әһәмиятле.

Бервакыт Изутсу остазыннан шулкадәр күп илләрне гизүенең сәбәбен сорый. Муса әфәнде аңа: «*Аллаһның могъҗизави ярату галәмәтләрен күзәтү өчен*», дип җавап бирә. Бу җавап Изутсуның хушын җибәрә. Муса әфәнде китаплар укуны икенче планга куеп, төп игътибарны табигать яшәешен һәм кешеләрне, аларның тормышын күзәтүгә юнәлтеп, Аллаһның никадәр олуг ярату көченә ия булуы турында уйланырга тәкъдим итә. Үзенең туган мәдәнияте өчен дә мондый яшәеш фәлсәфәсенең ят нәрсә булмавын белеп үскән Изутсу бер мөселманнан мондый сүзләр ишеткәч хәйран кала.

---

[1] Shiba, Ryōtarō (1993). Nijisseikimatsu no yami to hikari. Tokyo: Chūō Kōronshinsha. Чыгынакны искә алган мәкалә: Nurullah Sat. Abdürreşid İbrahim ve Musa Carullah’ın Talebesi Toshihiko Izutsu’nun Hayatı Eserleri: Türklere ve İslam’a Bakışı. Bilig. 2020, № 95. 97–122 s.

Изутсуның хатирәләреннән Муса әфәнденең чыганакларны яттан белүгә никадәр әһәмият биргән булуы аңлашыла. Беркөн Муса әфәнде Изутсуның китаплар тулы бүлмәсен күргәч: «*Боларның никадәрен яттан беләсең?*» – дип сораган. Изутсу яттан белгән китаплары юклыгын әйткәч, остазы: «*Синең кебекләр өйләрен сыртларына йөкләп йөргән адәм кыяфәтле әкәм-төкәмнәрдер. Галим мондый булмый. Ни генә эшләргә теләсәң дә, ул өлкәдә язылган төп әсәрләрне ятларга тиешсең. Өстәвенә, үз фикерләрен бик күпкырлы бер шәкелдә иркенләп уртага куймыйча, галим дип атала алмас*»,– дип нәсихәтен бирә.

Бервакыт Изутсу үзенең танышы булган Окава Сумәй (1886–1957) исемле атаклы япон фәлсәфәчесенең аңа биргән гарәп телле 600 сәхифәлек бер китабын Муса әфәндегә күрсәтә. Муса әфәндене бу китап кызыксындыра һәм ул Тошихикодан карап чыгарга дип сорап ала. Муса әфәнденең ул китапны никадәр йотлыгып укый башлавын күргән Тошихико аның кире үзенә әйләнеп кайтачагыннан өметен өзә, чөнки хөрмәтле остазыннан китапны кире сорап алырлык кадәр әрсез булмый. Әмма бер атна дигәндә теге китап иясенә кайта, чөнки берничә көн дигәндә Муса әфәнде аны ятлап өлгерә.

Япониядә чагында Муса әфәнде матди кысынкылык кичерә. Аның, хәтта, бүлмә яллап торырлык акчасы булмый. Шуңа бер конторада торган зур шкаф яллап, эчендә куна. Изутсу остазының акчасызлыгы сәбәпле кичергән тагын бер вакыйга турында язып калдырган. Көннәрдән бер көнне Муса әфәнде үзен бер теш табибына алып баруын үтенгән. Анда Муса әфәнде авызындагы берничә алтын тешен алдырып аны сата һәм шуннан кергән акчага көн күрергә мәҗбүр була.

1983 елда Муса әфәндене искә алып язган бер мәкаләсендә Изутсу болай ди: «*Тормышта яхшы остазлар белән очрашу мөмкинлекләре бик аз була. Мин яшь чагымда һичнинди шарт вә искәрмәсез ихтирамга лаек булган һәм миңа академик дөньяның ишекләрен ачкан бер кеше белән очрашкан идем. Ул татар мөселман Мусадыр. Гомере дәвамында кеше мондый форсатка бик сирәк юлыга. Якынлашып килгән II нче Дөнья*

*сугышының адым тавышлары инде ишетелә башлаган бер чакта күтелмәгән бер шәкелдә ул Япониягә килгән иде. Мине онығы сыман якын иткән Габдерәшит Ибраһим Мусаның килүе турында хәбәр биргәндә аны яшь, әмма булган кадәр атаклы бер кеше буларак сурәтләгән иде. Һич онытмаячакмын, бер бәйрәм көнендә Ибраһим мине утлары ялт-йолт килеп Йойоги*[1] *күкләрен балкытып торган мәчеткә алып керде. Мин шулкадәр тәэсирләндем ки, төштә кебек идем. Муса янына барып баскач: «Бу минем онығым»,* – дип, мине аның белән таныштырды. *Соңрак Муса белән бергә Сибәвәйһиның грамматика китабыннан гарәп теле һәм ислам фәлсәфәсе белән шөгыльләндек. Бернинди дә китап кулланмадык. Чөнки йөзләрчә томнар, меңләрчә сәхифәләр Мусаның хәтерендә иде. Аның белән танышуым минем академик юлга баскан ноктамдыр*».

Изутсуның ише Тойоко ханым да иренең Муса әфәнде белән танышуы һәм мөнәсәбәтләре турында үзенең бер әсәрендә язган. Бервакыт Габдерәшит хәзрәт Изутсуны кунакка чакыра. Изутсу килеп җиткәч, хәзрәт аңа: «*Бүген сиңа бик әһәмиятле хәбәрем бар. Бүген кич мәчеттә бер зур галим булачак. Гарәпчәсе миненекеннән күпкә яхшырак. Шулкадәр яхшырак ки, минем гарәп телен белүем аныкы белән чагыштырырлык түгел»,* – дип, үзенә ияртеп мәчеткә юл тота. Ул кич Токио мәчетендә Кадер кичәсе[2] үткәрелә. Мәчеткә якынайгач, берәүнең анда бик моңлы тавыш белән Коръән укыганы ишетелә башлый. Коръән укучы Муса әфәнде булып чыга. Тойоко ханым Изутсуның Муса әфәндене беренче мәртәбә күрүен шулай сурәтләгән: «*Кыйбла тарафына иелә төшеп михраб алдында ябык гәүдәле олы яшьтәге бер кеше утыра иде. Җыерчыклар сарып алган зәгыйфь гәүдәсенә соры төсле җүббә, башына шул ук төстә бер таккә*[3] *кигән. Коръән тилавәт кылганда алны-артны белмичә онытылып укырга күнеккән*

---

[1] Йойоги – Токионың төньягында урнашкан бистә.

[2] Кадер кичәсе рамазан аеның 27-се булса, хикәя ителгән вакыйга 1938 елның 19 ноябрендә була.

[3] таккә – баш киеме, кәләпүш.

*булуы күренеп тора иде. Изутсу: «Бумы зур галим?» дип сорагандай итеп Ибраһимга карый. Укылган Коръән аһәңнәре тыңлаучы кешеләрнең җаннарына үтеп керә, мәчеттә серле бер мохит хакимлек итә...».*

Намаздан соң Ибраһим казый Җаруллаһны Изутсуга үзенең якташы буларак тәкъдир итә, аның яшь чагында ук белем алу өчен Бәйрутка баруын, соңыннан Багдадта бер университетта мөгаллимлек кылганлыгы турында сөйли. Изутсуны исә «миннән гарәп телен өйрәнүче шәкертем» дип таныта. Бу танышу ахырында Җаруллаһ үзенең классик гарәп телен бик яхшы белүен белдерә һәм бу сүзен кабатлап ассызыклый. Изутсу Җаруллаһның үзенә тәмам инану хисе белән әйткән сүзләреннән югалып кала һәм үзен бик бәхетле итеп тоя.

Берничә көн узгач, Изутсу дәрес алу максаты белән, Ибраһим хәзрәт сызып биргән харитага карап, Муса әфәнде урнашкан урынны эзләп таба. Соры төсле җим белән сыланган, тышкы диварының бер өлеше җиргә иңгән ул кечкенә генә алачык бик сәләмә булып чыга. Муса әфәнде:

– Сибәвәйһинең[1] «Китаб»ын[2] укыганың булдымы? – дип сорый һәм аның гарәп теле белеменең иң мәшһүр классик әсәре булуын ассызыклап,– Шуннан башларга тиешбез,– ди.

Изутсу:

– Әмма миндә ул китап юк, миңа аны башта сатып алырга кирәк,– дигәч, Муса әфәнде:

– Китапның кирәге юк (һәм башына ишарәләп), барысы да монда,– ди.

---

[1] Сибәвәйһи (Әбу Бишер Гамр ибне Госман әл-Басрый; милади 760–797) – гарәп тел галиме, филолог, Басрада оешкан тел мәктәбе вәкиле.

[2] «Китаб» («Әл-Китаб») – классик гарәп теленең фонетикасын, морфологиясен һәм синтаксисын сурәтләгән күпсанлы бүлекләрдән тупланган китап. Хезмәт «Грамматика Коръәне» исемен казана. Һәр бүлектән соң, аңлатмалар китерелә, Коръәннән һәм борынгы гарәп шигъриятеннән мисаллар китерелә. Мисаллар сурәтендә бер меңнән артык шигырь китерелгән, аларны иҗат иткән шагыйрьләрнең һәм галимнәрнең, шул исәптән, башка беркайда да искә алынмый торган илле кешенең исемнәре аталган.

Изутсу Муса әфәнде әйткән бу сүзнең мәгънәсенә төшенеп өлгергәнче, остазы «Яз!» дип боера. Изутсу дәфтәрен ачарачмас, Муса әфәнде күзләрен йомып, «Беренче сәхифә» дип, дәресне яздыра башлый. Һәр хөкемне бәян иткәннән соң, аны тәфсилләп аңлата, шуңа өстәп җаһилият чоры гарәп шигъриятеннән мисаллар китереп беркеттерә. Туктап, тукталып тормастан, ял итмичә, озак итеп сөйли, аңлата, үрнәкләр китерә. Изутсу дулкынлануыннан, тырышып-тырмашып язып утыруыннан манма-су тиргә бата. Бер мәлдә Муса әфәнде кисәк кенә, «Бүген бу кадәр!» дип, өзеп куя да күзләрен ача. Изутсу дәфтәренә карый – аның ун бите язу белән тутырылган була.

Шулай итеп, Изутсу яттан сөйләп сабак биргән остазыннан гарәп теле нечкәлекләрен өйрәнә. Дистәләгән еллар узгач, гарәп телен камил үзләштергән Изутсу, Япониядәге беренче ислам профессоры буларак, Сүриягә барып чыга. Анда ул Җаруллаһның аңа яттан сөйләп яздырган гарәп теле грамматикасы китабын сатып ала. Үзенең яшь чагындагы язмаларын Сибәвәйһинең «Әл-Китаб» дип аталган хезмәтендә язылганнар белән чагыштырганда, ике текстның тәмам тәңгәл булуын үз күзләре белән күреп хәйран кала.

Озак еллар узгач, Тойоко ханым үзенең китабында, исемен М. хәрефе белән белдереп, Изутсуның дусты булган бер япон профессорын искә ала: бервакыт бу профессор М. Каһирәдә UNESCO тарафыннан үткәрелгән симпозиумда катнаша[1]. Шул конференция дәвамында берәү профессорның кулына кагылып: «Япониядә Изутсу исемле бер шәкертем бар иде, аны беләсеңме?»,– дип сорый да: «Аңа миннән сәлам әйт»,– дип өстәп куя. Профессор М. сәлам әманәтен адресатына ирештерә. Остазының сәламен алгач, Изутсу бик хисләнә, күңеле тулып күзләре яшьләнә. Шул мәлдә, йөрәгендә кузгалган самими хисләрен тыя алмыйча, Изутсу Муса әфәнде-

[1] Муса әфәнде 1948 елда Каһирәгә килә. Шул ук елны UNESCO оешмасы анда үзенең еллык корылтаен үткәрә. Конгресста Япониянең әлеге оешмага әгъза булып керүе мәсьәләсе беренче мәртәбә карала.

нең: «*Утыртылган урынында черегән агач (кебек) булу яхшы нәрсә түгелдер, Изутсу!*» дигән сүзен кабатлый.

Тошихико Изутсу зур шәркыятьче галим, дөнья күләмендә танылган ислам белгечләреннән берсе булып җитешә, гарәп теле белгече һәм полиглот була, Коръәнне япон теленә тәрҗемә итә, ислам дине һәм аның фәлсәфәсе, тел фәлсәфәсе, дини мистицизмга, шул исәптән суфичылыкка кагылышлы фәнни хезмәтләр яза.

Муса әфәнде Япониядә җиң сызганып эшләп яткан мәлдә, 1939 елның сентябрь аенда Икенче җиһан сугышы башланып китә. Бу сәбәптән, шул елның азагында Муса Бигиев Әфганстанга күчеп, шунда мәдрәсә ачарга карар кыла да, Япониядән китеп бара, дип яза М. Гөрмәз[1]. Башка чыганакларга караганда, Муса әфәнде Токиодан 1939 елда түгел, 1938 елның азагында ук китеп барган. Имеш, галим, Чин аша үтеп, Һиндестанга барып урнашуны ниятләгән була[2]. Безнең эзләнүләребез нәтиҗәсендә, Муса әфәнденең Япониядән 1938 елда әле китмәгән булуын раслый торган дәлилләр табылды: 1939 елның апрель аенда Төньяк Чин һәм Монголиядән килгән мөселманнарны Токио мәчетендә олылап каршы алу тантанасы үткәрелә һәм күмәк фотосурәт алына. Ул фотода Муса әфәнде дә бар. Димәк, Муса Бигиев Япониядән 1938 елда ук китеп бармаган булган. Өстәвенә, бу очракта Муса әфәндедән сабак алган Тошихико Изутсу остазыннан аңа яттан сөйләнгән ун гарәп грамматикачысы турындагы китапны язып алып һәм үзләштереп өлгермәгән булыр иде.

## Яңа Җиһан сугышы. Һиндестан тозагы. Хәмидулла-Хан

Минем фикеремчә, Япониядәге сәфәрен тәмамлаганнан соң, Муса әфәнде ни Әфганстанга барып урнашуны, ни Һиндестанда яшәп калуны ниятләмәгән. Аның нияте Төркиягә барып урнашу булган. Һәрхәлдә, Муса Җаруллаһ һич тә Чин (Кытай) аша узуны күздә тотмаган булса кирәк, чөнки 1930 елда Советлар Берлегеннән качып киткән вакытта

[1] Görmez M. Күрс. хезм. Б. 47.
[2] Kanlıdere A. Күрс. хезм. Б. 129.

Чин хөкүмәте аны илдән чыгып китәргә мәҗбүр иткән була. Димәк, Муса Җаруллаһ өчен Чинга юл ябык һәм ул үзе дә моны бик яхшы белгән, куылу ачысын татып караган булган. Япониядән киткән вакыты да 1939 елның II Җиһан сугышы башланган көзе булырга тиеш.

Ни генә булса да, Төркиягә юл тоткан галимгә Һиндестан аша узарга туры килә һәм анда ул Бөекбритания колониаль администрациясе тарафыннан кулга алына. Бу аңлашыла да, чөнки Бөекбританиягә каршы сугышкан көчләр ягында булган Япониядән чыгып, шул ук көчләр тарафында булган Төркиягә сәфәр кылучы олуг мөселман галиме, әлбәттә, колониаль идарә игътибарын җәлеп итми булдыра алмаган.

Һиндестанның Пәшавар вилаятендә[1] кулга алынганнан соң, Муса Җаруллаһ алты айга якын вакытын авыр шартларда төрмәдә үткәрә. Олуг галимнең төрмәгә атылуы турындагы хәбәр Һиндестанның үзәгендә урнашкан Бһопал кенәзлеге әмире Мөхәммәд Хәмидулла-Ханга барып ирешә. Әмир шундук, колониаль администрациягә баш орып, Муса әфәндене төрмәдән коткара – галимне күзәтү астындагы йорт тоткыны хәленә күчерәләр. Шулай итеп, Бһопал әмиренең тырышлыгы белән Муса әфәнде, кырыс зиндан шартларында интегүдән котылып, тоткынлыгының калган өлешен Хәмидулла-Хан җаваплылыгында аның сараенда яши[2].

Муса Бигиев, колониаль идарәнең әсире булып, Бһопалда 1945 елга кадәр калган дип фараз кылып була. Сак астында тотылу режимы тәмамлангач, алда күрсәтеләчәк документларга бинаән, аның башта Дәһлигә киткән булуы, аннары 1947 елга кадәр Бомбәйдә яшәгән булуы ачыклана. Тоткынлыкта үткәргән елларда Муса әфәнде дистәгә якын китап язып өлгергән була. Галимнең үзеннән калган хәбәрендә аның Һиндестанда язып бастырган китапларының саны сигез-тугызга җитә. Биредә Муса Җаруллаһның Һиндестаннан язган

---

[1] Пәшавар вилаяте хәзерге Пакьстанга карый. Муса Бигиевнең биредә Әфганстанга барышлый кулга алынуы турында Йосыф Уралгирәй язган булган. Кара: Uralgiray. Önsöz, s. XVIII.

[2] Kanlıdere A. Күрс. хезм. Б. 130.

бер хатыннан өзек китерәбез: «*Бүген мин сау-сәламәтмен. Җаным тәндәдер. Фәкать әгъзаларым соң дәрәҗәдә хәлсез. Куәтем юк. Аякларыма бассам, бик зур авырлык белән хәрәкәт итәм. Һиндестанда кулга алындым. Бик хаста идем. Бһопалда калдым. Анда 8 китап бастырдым. Алга китеш булды. Моннан элек Каһирәдә 5 китап бастырдым. «Әл-Вәшига фи накыд гакаид әш-шига» исемле китабым Гарәбстан вә Һиндестанда гадәттән тыш тизлек белән таралды. Нөсхәсе 50 рупиягә кадәр күтәрелде. Сатуда калмады, китапларны үз исәбемә бастырдым, фәкать бөтен файдасы китапчыларга булды.*

*«Әл-Вәшига» сәбәбе белән Иран, Гыйрак вә Йәмән юллары миңа тәмамән ябылды. Шуңа күрә инде Лондон тарафларына сәяхәт ниятләдем. 1945 ахырларында Бһопалда тоткынлык хәятеннән котылдым. Сәяси зарурәтләр өчен Дәһлидәге хөкүмәт хозурына юнәлдем. Бер ай кадәр Дәһлидә яшәдем. 1946 да апрель башларында Бомбәйгә килдем. Шул көннән бүгенгә кадәр хастамын. Авыруым гаять көчле булды. Докторлар июнь башларында мине зур санаторияләрнең берсенә урнаштырдылар. Анда ике ай кадәр яттым. Җисемемдә вактөяк фәкать сызландыра торган гамәлиятләр*[1] *ясадылар. Вөҗүдемдәге яралардан тәмам котылдым. Хатаханәдән чыктым. Фәкать соң дәрәҗәдә зәгыйфь идем. Әгъзаларымда хәрәкәт куәте калмаган. Телгә алынган санаториядә аерым бер бүлмә, ашау-эчү, доктор күзәтүләре вә дарулар өчен 3000 рупиядән артык акча түләдем. Шәгъбан вә рамазан айларында ятакта идем. Ураза тоту, тәравих намазларына бара алу көчемнән килми иде. Шәүвәл вә зөлкагъдә айларында да ятакта калдым. Зөлхиҗҗә башларында көчле вә гаҗәеп бер хасталыкка тотылдым. Докторым мине янә зур клиникаларның берсенә урнаштырды. Анда ашату юк иде. Даруларга да мин түли идем. 16 гыйнварда яттым, 26 сында чыктым. 500 рупия түләдем. 18 гыйнварда җибәргән гаять әһәмиятле мәктүбегез миңа 26 гыйнварда тапшырылды. Шул көндә үк укып чыктым, 2–3 көн йокым качты.*

[1] гамәлият – операция.

*Соң дәрәҗә тәэсирле вә гаять әһәмиятле мәктүбегез бөтен вөҗүдемә, калебемә һәм гасабларыма*[1] *куркыныч сурәттә тәэсир итте. Миңа һәм шатлык бирде, һәм дә калебемне вә акылымны вәһемнәр*[2] *дулкыннарына батырды. Әһәмиятле бу мәктүбегез аркасында сезгә меңләрчә, миллиардларча тәшәккер итәмен. Үтенәмен, мәктүбегезне ачык языгыз:* (انا الغريق فما خوفى من البلل)»[3].

Муса әфәнденең Һиндестанда дөнья күргән гарәп телле хезмәтләре 1944 елда басыла башлап, соңгылары 1946 елда дөнья күрә. Эзләнә торгач, аларның хәзерге вакытта мөмкин кадәр тулы булган исемлеген төзедек:

***Сахифату әл-фәраъиди***. Бһопал, 1944. 188 б. («Исламда мирас бүлү бюллетене». Муса әфәнденең математикага карата булган сөюен гамәлгә ашырып, бу фәннең алымнарын шәригать хөкемнәре рәвешенә китереп, практикада кулланырга өйрәтә торган үзенчәлекле әсәр);

***Сарфу әл-Куръәни әл-кәрими***. Бһопал: Central India Press, 1944. 104 б. («Коръән грамматикасы». Ә. Канлыдәрәнең язуына күрә, китапның ул күргән данәсендә Муса әфәнденең үз кулы белән язган мондый сүзләр бар: «*Бу китапны Кәшгарда бу шәһәрнең юмарт әһалисе арасында кунак булганда Сәйид Гомәр Ахунбайның өендә яздым. Шәгъбан вә рамазан 1349, 1931 ел башларында*». Бу китапта гарәп телендә фигыль төрләнеше шәкелләре Коръәндә кулланылган фигыльләр мисалында өйрәтелә. Муса әфәнденең үз сүзләре белән әйткәндә: «*Бу китапны язудан максатым Коръән кәлимәләрен өйрәтү аркылы Коръән телен өйрәнүне кулайлаштырудыр*». Китапның баш өлешендә мондый кереш сүз урнаштырылган: *«Гарәп телен өйрәнүнең кирәклеге, гарәпләрнең тамырлары һәм катламнары, гарәп телен фәнни калыпка салу кебек мәүзуглар бәян ителде. Тәурат, Инҗил һәм Йәҗүҗ кебек*

---

[1] гасабларыма – нерваларыма.

[2] вәһем – буш уйлар; фантазияләр.

[3] «Мин тәмам баттым, шуңа күрә чыланудан курыкмыйм». Милади 915–965 елларда яшәгән Мөтәнәбби атлы гарәп шагыйре иҗатыннан.

*Коръәндә телгә алынган кайбер сүзләрнең этимологиясенең әле бүген дә хәл ителмәгәнлеге белдерелә. Аеруча әсәрдә тел фәлсәфәсенә кагылышлы бер тикшеренү бар»*);

***Китабу тәртиби әс-сүвари әл-кәримәти вә тәнасүбүһу фи ән-нүзүли вә фи әл-мәсахифи***. Bһопал: Central India Press, 1363/1944. 344 б. («Коръән сүрәләренең иңүе һәм мосхәфләрдә билгеле тәртиптә урнаштырылуларына күрә үзара мөнәсәбәтләре». Әсәр Коръән сүрәләренең кабул ителгән урнашу тәртипләре һәм аларның иңү нәүбәтләренә багышланган);

***Илһаму әр-рахмани фи тәфсири әл-Куръәни*** *галә усули әл-имами Шаһ Вәлиуллаһ әд-Дәһләви мин ифадати әл-имами әс-Синди Губәйдуллаһ ибни әл-Ислами әл-ләти тәләкъкаһа минһу Муса Җаруллаһ.* Карачи: Бәйт әл-Хикмәт, 1363/1944. 2 томда: 1 нче том 344 б.; 2 нче том 248 б. (Бу хезмәт турында 1932 ел хәлләре бүлекчәсендә язылды);

***Хуруфу әваъили әс-сүвари***. Bһопал, 1944. 235 б. («Сүрәләрнең беренче хәрефләре». Бу әсәрендә Муса әфәнде Коръән сүрәләренең байтагының башламында аерым-аерым хәрефләрдән гыйбарәт булган беренче айәтләргә аңлатма бирә. Аның әйтүенчә, бу хәрефләр ислам тарихының һәр дәверендә үзенчәлекле сурәттә тәфсир кылынганнар, әмма дөрес мәгънәсен ачып бирә торганы булмаган);

***Тәъмину әл-хәйати вә әл-әмлаки***. Bһопал, 1944. 22 б. («Хәят һәм мал-мөлкәтне тәэминләштерү (страховать итү)». Китапта ислам күзлегеннән банклар мәсьәләсе һәм Коръәннең риба, ягъни өстәмә процент алуга корылган кредитлау турында хөкем кыла торган аяәтләре тәфсир ителә);

***Китабу әс-сүннәти***. Bһопал, 1945. 119 б.[1]. («Сөннәт китабы». Бу хезмәт үзләрен «Әһле Коръән» дип атап Пәйгамбәр

---

[1] Бу китап белән Һиндестан силсиләсе тугыз данә әсәргә җитә. Әлеге әсәр турында Зәки Вәлиди Тоган хәбәр итә (Togan, Zeki Velidi. Musa Cârullah Begi’nın Hayatı ve Eserleri. Selâmet. 23 Kasım 1949. 5. Cilt. 105 Sayı. S. 16.). Ул китапның миндә хәтта ксерокста ясалган нөсхәсе дә бар иде, әмма кызганыч, аны компьютерда җыю сылтавы белән миннән сорап алган оешмадан кире кайтмады.

хәдисләрен шәригать чыганагы итеп кабул итүдән баш тартучыларның ялгышуларын фаш итүгә багышлана);

***Низаму әл-хилафәти әл-исламийәти әр-рашидәти әлйәүмә фи гусури әт-тәмәддүни***. Бһопал, 1946. 42 б. («Бүгенге мәдәният дәверендә чын ислам хакимиятенең (хилафәтнең) төзелеше». Бу әсәрне таныткан бер игъланда «чын ислам хакимияте гамәлгә ашырылмыйча, ислам галәменең көчле, сүзен тыңлата, карарларын үти алырлык бер куәткә ия булуы мөмкин түгелдер», диелә);

***Әл-Банку фи әл-ислами***. Бһопал, 1946. (битләр саны билгеле түгел). («Исламда банк». Бу хезмәт исламча банк эше, фаъиз (процент) һәм бу мәсьәләгә караган хөкемнәргә багышлана. Русиядә яшәгән дәвердә язылган «Зәкят» исемле әсәрнең гарәп теленә тәрҗемә ителеп камилләштерелгән һәм тулыландырылган нөсхәсе булырга мөмкин);

***Әл-Канунү әл-мәдәнийу фи әл-ислами***. Бһопал, 1946. (битләр саны билгеле түгел). («Исламда конституция». «Сарф әл-Коръән» исемле китабында бу әсәргә багышланган белдерүдә Муса әфәнде болай дигән: «Бу китапта большевик кануннары белән ислам илләренең Көнбатыштан инде алган яки алырга әзерләнгән кануннарны бәян иттем»).

Әлеге исемлек тулы булса да, хәзерге вакытка кадәр Һиндестанда тоткынлык дәверендә язылган китапларның берикесе генә табылып тәрҗемә ителә башлады. Олуг галимнең Һиндестанда үткәрергә мәҗбүр булган еллары турында Муса әфәнденең дусты, күренекле төрек журналисты Гомәр Рыза Догрул әфәнденең[1] язуынча, Муса Җаруллаһ Һиндестанның

[1] Гомәр Рыза Догрул (Ömer Rıza Doğrul, 1892–1952) – төрек тарихчысы, дин галиме, фәлсәфәче, тәрҗемәче, җәмәгать эшлеклесе, нашир, журналист, публицист. Каһирәдә Әл-Әзһәр университетын тәмамлаганнан соң Каһирәдә журналист булып эшли. 1915 елда Истанбулга күчеп килә. Фикердәшләре белән бергәлектә Төрек ислам энциклопедиясенә (İslâm-Türk Ansiklopedisi) нигез сала. Догрул әфәнде «Tanrı Buyruğu Kur'ân-ı Kerîm'in Tercüme ve Tefsîr-i Şerîfi» дип аталган латин язулы беренче төрек телле Коръән тәфсиренең авторы да. 1951 елда Пакьстанда Ислам Конгрессы эшендә катнаша. Төркия парламентында (Төркия Бөек Милләт Мәҗлесе) Тыш-

Бһопал вилаятендә тоткын булган чорда Коръән кәримнең сүрәләре һәм айәтләре хакында бер әсәрен каләмгә алган булган. Аны, хәтта, бастыруга һәм таратуга ирешә алган. Әлеге хезмәтен Муса әфәнде шул вилаятьнең шаһзадәсенә, кыен хәлдә калган чагында аңа ярдәм кулын сузган Мөхәммәд Хамидулла Ханга ихтирам һәм шөкеранә йөзеннән бүләк буларак тәкъдим иткән. Бу турыда Догрул әфәнде болай дип яза: «*Әсәрне Һиндестанның бу мөселман шаһзадәсенә тәкъдим итүенең сәбәбе дә ул вакытта хөрмәтле остазыбызны әсирлек күзәтелүе астында тоткан Һиндестан хөкүмәте каршында арадашлык итеп, аның азат ителүенә һәм иреккә чыгарылуына мөмкинлек бирүедер. Бөек остаз бу игелекнең шөкеранәсен үтәү буларак бу искитәрлек әсәрен Бһопалда бастырган һәм бу шөкеран вазифасын үтәү мөмкинлеген тапкан. Бу шөкеранәгә без барыбыз да кушылабыз һәм барыбыз да бөек Төрек фикер иясенә һәм галименә ярдәм итеп, әсирлектән коткарган һәм иреккә чыгарткан бу мөселман шаһзадәсенә ратуларыбызны һәм ихтирамларыбызны белдерәбез*»[1].

Минем фикеремчә, биредә сүз Муса әфәнденең «***Китабу тәртиби әс-сувари әл-кәримәти вә тәнасүбүһу фи ән-нүзүли вә фи әл-мәсахифи***» исемле китабы турында бара. Телгә алынган бу китапның бер өлеше 1949 ел дәвамында Гомәр Рыза әфәнденең Төркиядә чыгарган «Selâmet» исемле журналында басыла. Бу турыда сүзебез алда әле.

## Җиһан сугышыннан соң. Йосыф Уралгирәй. Әхмәт Бигиев

Инде Муса әфәнде тормышының соңгы еллары турындагы сүзебезне дәвам итик.

Йосыф Уралгирәйнең[2] язганнарына күрә, остаз әле һаман да Бомбәйдә булган вакытында, ягъни 1946 елда аңа бер хат

---

кы элемтәләр бүлегендә хезмәт итә. Бу мәкаләдә искә алынган Мехмет Акиф Эрсойның кияве.

[1] Doğrul, Ömer Rıza. Yeni Selâmet. T. IV, Sayı 12–80. 30 март 1949. S. 4.

[2] Йосыф Уралгирәй (Йосыф Уралгирәй Вәлишаһ; 1915–1986) –

яза. Ул хатта остаз Йосыф әфәндедән аңа тиз арада Мисыр визасын әзерләп җибәрүен үтенә. Уралгирәй ул чакта Каһирәдә яшәгәнгә, Мисыр визасын алу кыен[1]. Нәтиҗәдә, Уралгирәйнең язуынча, 1947 елда Муса Җаруллаһ Һиндестаннан Каһирәгә килеп төшә. Биредә Муса әфәнде башта шәһәр үзәгендә урнашкан «Әл-Хөсәйни» мәчете янындагы урта хәлле бер кунакханәгә туктала, әмма Уралгирәй хөрмәт йөзеннән остазын үз өенә кунак итеп ала. Остазы белән очрашуны ул болай сурәтләгән: «*Алып өемә китердем. Бик талчыккан иде. Хәятеннән шикаятьче иде, тәмам гарык булган иде. Берничә көн ял иткәннән соң хәле шактый яхшырды. Бер көн иртәнге аштан соң арабызда шундый сөйләшү булып алды. Мәрхүм болай диде: «…Улым, сиңа хәер догаларымның ахыры юк… Күрәсең, мин бик картайдым. Һәм дә эчемдә тынмый торган дәвамлы бер сызлану бар. Гомерем буенча төрек-мөселман кардәшләремә сөенә-сөенә хезмәт иттем. Төркестанны кичеп, Финляндиягә бардым. Аннан телефон белән Рус-Совет оешмаларын таптым. Аларга хатыным Әсма белән телефон аша күрешүне теләгәнемне белдердем. Хатынымны табып, телефонга китерделәр. Сөйләшкән вактыбызда Әсма миңа: «Муса, сине аслән гафу итмәячәкмен. Алты баланы минем башыма калдырып качтың. Дөньям чәлпәрәмә килде»,– диде. Әлбәттә, бичараларга күпне кичерттеләр. Бүгенге хәлләрен белмим. Картайдым. Моңа карамастан коммунистлар мине үтерәчәк булсалар, итсеннәр, бу җинаятьне дә кылсыннар. Фәкать, мин карар кылдым. Кире кайтачакмын.*

---

Россия хакимиятеннән качып Румыниягә һиҗрәт кылган Кырым татарларыннан. Язучы, галим, тарихчы, җәмәгать эшлеклесе, педагог. Төрки мөһаҗирлекнең күренекле вәкиле, күпсанлы китаплар авторы, Муса әфәнденең шәкерте һәм дусты.

[1] Йосыф Уралгирәй кимендә 1944 елдан бирле Каһирәдә яшәгән була һәм биредә төрки эмиграция даирәләрендә актив иҗтимагый эшчәнлек белән шөгыльләнә. Тулырак мәгълүмат өчен карагыз: Хайрутдинов А. Г. Из истории туркестанской эмиграции: «Туркестанское благотворительное общество» в Каире. Minbar. Islamic Studies. 2020; 13(4):824–844. (DOI 10.31162/2618–9569–2020–13–4–824–844)

*Бердәнбер максатым: хатынымның аякларына капланып гафу үтенәчәкмен. Бу уйларымны һәм карарымны беренче мәртәбә сиңа ачыклыймын. Сине бик яратам. Зинһар, бу паспортны ал, улым. Миңа Русиягә кайта алуым өчен виза ясат. Беттем мин бу хәсрәтләрдән»,– диде, ә аның яшен кебек ялтыраган зәп-зәңгәр күзләреннән тын гына тамчы-тамчы яшь ага иде. Мин дә күңелем нечкәрде. Каршымда мин ихтирам иткән, дөньяга танылган бер галим, сыгылып төшкән фани бер адәм баласы иде. Ватанын, динен һәм инкыйлабны яратуы хакына зур өметләр асрап тулы бер гомерен фида кылган бер мөҗаһиднең рухын гыйсьян иттергән җанлы бер дулкынлануны йөзендә күрә идем... Тын гына бергәләп еладык...»*[1].

Уралгирәй язып калдырган хатирәләрнең гаять кыйммәтле булуы нисбәтле, биредә аннан тагын бер парча китерсәк, зыян итмәс: «*Янә ул күзләрдән калебендәге тирән сызлануның көчен белдергән күз яшьләренең акканын шундый бер вакытта күрдем: Советларда үзеннән соң үсеп җитешеп очкычлар инженеры булган углы Әхмәт Икенче дөнья сугышында үзе кулланган сугыш очкычы белән алманнарга сыенган булган. Якын дусларымның арадашлыгы белән Әхмәтнең Алманиядәге адресын таптырып, хат алышуларын җайга салган идем. остазыбыз Әхмәттән килгән хатларны куенында саклар, шунда йөртер иде. Мөшфикъ*[2] *бер атаның калебендә янган хәсрәтенең, ярсу һәм ташып торган сөюенең галәмәтедер бу... Чыгарып әледән-әле укыганда «Әхмәтем, балам», дип ул бөек остаз күз яшьләрен тыя алмый иде.*

*Әхмәт килеп әтисен күрергә тели иде. Акчасы юк иде. Атасыннан юл чыгымнарының тотылуын үтенә иде. Фәкать, никадәр үкенеч, ни мин, ни остаз моның чарасын таба алмадык. Ата белән угылын кавыштыра алмадым һәм исемә төшкән саен бу көнгә кадәр һаман моның басымы астында яшимен.*

---

[1] Uralgiray. Önsöz, s. XVIII.

[2] мөшфикъ – шәфкатьле, кызгана белә торган.

*Әйе, вазгыять мөәссир*[1] *иде. Мин остазымның фикерләренә ихтирам күрсәтү белән бәрабәр аның бу яшендә большевикларга үз аягы белән китеп хакарәт күрүенә тарафдар түгел идем. Хәтта үтермәсәләр дә мыскыл итәчәкләр һәм аны мең дә бер яктан изәчәкләр иде. Бу карашымны төрле яклардан тикшереп үзләренә тәкъдим иттем һәм ахырда: «Ни булса да, Истанбулга барачаксыз. Анда сез күрешергә тиешле Кырым раһбәре Җәгъфәр Кырымер*[2] *һәм башка зур кешеләребез бар. Бу нәрсәләр турында алар белән бергәләп уйлашырсыз», – дидем. Фикеремне дөрес дип тапты. Шулай итеп аны Истанбулга озаттым. Вазгыятьне Җәгъфәр Кырымер бәйәфәндегә алдан ук белгертеп куйган идем»*.

Биредә Муса әфәнденең углы Әхмәт турында яңа табылган фактлар белән уртаклашу урынлы булыр. Моның өчен Барри Рубин белән Вольфганг Шваниц исемле ике тарихчының 2014 елда басылып чыккан «*Nazis, Islamists, and the Making of the Modern Middle East*»[3] («Нацистлар, исламистлар һәм хәзерге Якын Көнчыгышның барлыкка килүе») исемле хезмәтләренә мөрәҗәгать итәргә кирәк булачак. Бу китапның 207 битендә Муса әфәнденең углы турында мондый сүзләр бар: «*Сугыш вакытында ул [Муса әфәнденең углы] совет истребитель очучысы була, бәреп төшерелә һәм алманнарга әсирлеккә төшә. Бигиев, этник татар буларак, Каһирәдә яшәгән һәм укыткан Муса Җаруллаһ Бигиев исемле күренекле мөселман*

[1] мөәссир – тәэсир итүче; тәэсирле.

[2] Җәгъфәр Сәед-Әхмәт/Сәйдәмәт (Кырымер фамилиясен 30 нчы елларда ала); 1889–1960) – эшчәнлеген Русия империясе дәверендә башлаган кырым-татар халкының сәяси, милли һәм идеологик юлбашчыларының берсе. 1917 елның декабрь аеннан башлап 1918 елның 26 гыйнварына кадәр Кырымда Чәләби-Җиһан җитәкчелегендә хакимлек иткән кырым-татар бәйсез хөкүмәтендә хәрби министр һәм тышкы эшләр министры була, 1918 елның апрель аеннан соң Сулькевич җитәкчелегендәге Кырым ягы хакимиятендә тышкы эшләр министры. Тарих, сәясәт тарихы һәм башка темаларга караган китаплар авторы.

[3] Barry Rubin And Wolfgang G. Schwanitz. Nazis, Islamists, and the Making of the Modern Middle East. Yale University Press, 2014. 340 p.

*дин әһеленең углы була. Өлкән Муса Әл-Хөсәйни белән 1930 еллар башында, Бөек мөфти оештырган халыкара очрашуларның берсендә танышкан була. Аның угылы бәреп төшерелеп, әсирлеккә эләккәннән соң, Муса аны Маутхаузен лагереннан азат иттерү өчен Әл-Хөсәйнигә мөрәҗәгать иткән булса кирәк. Әл-Хөсәйни Эйхманга*[1] *мөрәҗәгать итә, әмма Муса Гали Бөек мөфти тарафыннан оештырылган алман гаскәре бүлекчәләренә кушылудан баш тарта һәм, шул сәбәпле алман әсире булып кала. Сугыштан соң азат ителгән Муса Гали Алманиядә кала. 1949 елда Һамбургтагы Алман мөселман берлегенә (German Muslim League) керә».*

Бу мәгълүмат никадәр әһәмиятле булса да, аңа бер тәнкыйди күзәтү ясарга кирәк. Беренчедән, авторлар Муса әфәндедең углын Али, Муса Али, Муса Али Бигиев исемнәре белән телгә алалар. Бу, әлбәттә, хата: чөнки, беренчедән, остазның Мөхәммәт һәм Әхмәт исемле угыллары булганлыгы мәгълүм, икенчедән, Уралгирәй китабында китерелгән хатларда сүз нәкъ менә Әхмәт турында бара. Бу очракта Рубин белән Шваниц, мөгаен, я үзләре ялгышкан, яисә алар файдаланган чыганакның авторы ялгышкан. Сүз Муса әфәндедең углы турындагы мәгълүматны беренче булып биргән Симон Визенталь исемле журналистның китабы турында бара. Визенталь 1961 елда ук «*Ich jagte Eichmann*» («Мин Әйһманны ауладым») исемле хезмәт бастыра. Шуның 135 битендә ул Муса Галинең Алманиядә калуы, ә 140, 148–149 битләрдә аның Мөселман берлегенә кушылуы турында язган[2]. Исемгә караган бу хатаны истә тотканда, китапта китерелгән башка мәгълүмат дөреслеккә хилаф түгел: анда Муса әфәнде *Musa Jarullah Bigiyev* исеме белән искә алына, аның *distinguished Muslim*

[1] Эйхман (Отто Адольф Эйхман; 1906–1962) – нацист Алмания гаскәренең СС оберштурмбаннфюреры, үзе идарә иткән оешма мөдире буларак, яһүдләрнең нәселен корыту (геноцид) процессын гамәлгә ашыра һәм җитәкли, «Холокост архитекторы» буларак мәгълүм. Сугыштан соң Аргентинага кача, әмма 1960 елда «Моссад» хезмәткәрләре аны, урлап алып, Израильгә китерәләр һәм анда Эйхман мәхкәмә карары белән үлем җәзасына дучар ителә.

[2] Wiesenthal, Simon. Ich jagte Eichmann. S. Mohn, 1961. P.135.

*cleric* (танылган мөселман дин эшлеклесе) булуы, 1930 еллар башында Әл-Кодеснең Бөек мөфтие Әл-Хөсәйни белән танышкан булуы хәбәр ителә. Австриядә урнашкан Маутхаузен лагереның союздаш гаскәрләр тарафыннан азат ителгәнлеген истә тотканда, шунда әсир булган Әхмәт Бигиевнең Советлар Берлегенә ни рәвешле кире кайтмый кала алганлыгы да аңлашыла: ул чакта минем дәүәтием Гыйлметдин Хәйретдинов үзенең ике-өч авылдашы белән бергә шундый лагерьларның берсендә әсирлектә була. Дәүәтиемнең сөйләгәненә күрә, аларны әсирлектән союздаш гаскәрләр, аерым алганда, АКШ хәрбиләре азат итә. Азат ителгән совет хәрбиләренә, Совет иленә кайтмыйча, Америка Кушма Штатларына күчеп китү мөмкинлеге тәкъдим ителгән була. Димәк, Әхмәт Бигиев, мөмкинлектән файдаланып, ватанына кайтмаган.

Һәм искә алынган тикшеренүдән ясалырга тиешле иң мөһим нәтиҗә – Уралгирәй истәлекләрендә Әхмәтнең, качып китеп, үз теләге белән дошман тарафына күчүе турындагы сүзнең хакыйкатькә туры килмәве. Чыннан да, Уралгирәйнең язмаларына игътибар белән караганда, аның бу сүзләрне Муса әфәндемнең авызыннан ишетеп түгел, үзлегеннән әйткән булуы күренеп тора. Уйлап карасаң, әгәр Әхмәт фашистлар ягына үз ихтыяры белән качып киткән булса, ул, әлбәттә, Маутхаузенда интегеп ятмас иде. Әмма Рубин белән Шваниц тарафыннан телгә алынган Визентальнең мәгълүматларына караганда, Әхмәт әсир буларак лагерьда тотыла, аны эзләп тапкан Эйхманның тәкъдименнән баш тартуы сәбәпле, сугыш беткәнче лагерь газаплары эчендә калырга үзен дучар итә. Димәк, Уралгирәй я эшнең асылын белмичә ялгышкан, я хакыйкатькә туры килмәгән ул сүзне бер башка сәбәптән әйткән.

## Соңгы мәртәбә Төркиядә (сентябрь 1947–1948, декабрь)

Шулай итеп 1947 ел азагында кире Русиягә кайту теләгендә булып, аны тормышка ашыру юлларын эзләгән Муса әфәнде Истанбулга килеп төшә. Бу килүенең төгәл датасы әлегә билгеле түгел. Әмма Истанбулданиләр кичергәнен Га-

яз Исхакыйның кызы Сәгадәт Чагатайга язган хатларыннан чамалый алабыз. Мәшһүр ата белән аның кызы арасындагы язышуларны саклап калган күпсанлы хатларда Муса Җаруллаһның исеме беренче мәртәбә 1947 елның май аенда күренеп ала. Май аеның 3 ендә язылган хатында Исхакый мондый өстәмә калдырган: «*Һиндестандан, Бомбәйдән мәктүб алдым. Муса әфәнде бик картайган, хәлдән тайган, дип язалар. Бәлки, мескин, шунда үлеп тә калыр инде. Монда керергә үзенә мөсәгадә*[1] *итмиләр. Хәерле булсын*»[2].

Муса әфәндегә башта чикләрен ачмаган Төркия хөкүмәте, ниһаять, рөхсәт бирә һәм бөек галим Истанбулга аяк баса. Бу вакыйга Төркия зыялыларының игътибарыннан читтә калмый. Алар үзләре Муса әфәнденең кем икәнлеген белсәләр дә, Төркия халкының бу олуг галим хакында хәтерен яңарту кирәк була, чөнки аның Төркиядә 1932 елда булып алганыннан соң инде 15 ел вакыт узып киткән. Бу нисбәттә төрек матбугатында Муса әфәндегә кагылышлы мәкаләләр басылып чыгуы табигый.

Безгә мәгълүм беренче мәкаләнең «Doğan Güneş»[3] журналында 1947 елның 17 сентябрендә басылып чыгуы Муса әфәнденең Төркиягә сентябрьнең урталарында барып җиткән булуын тәгаен кылырга мөмкинлек бирә. Әлеге мәкаләне Мәхмүт Җәүдәт исемле кеше язып, аның исемен дә вакыйгасына күрә «Hoş geldiniz» («Хуш килдегез») дип куя[4]. Мәкаләдә болай диелә: «*Сүзебез замандаш, бөтен Төрек вә Мөселман дөньясы белгән мөхтәрәм шәхес Остаз Муса*

[1] мөсәгадә – рөхсәт, ягъни Муса әфәндене Төркиягә кертмәгәннәр.

[2] Исхаков, М. Г. Әсәрләр: 15 т. Т. 14.: хатлар һәм автобиографик язмалар [томны төз., текст. Һәм аңлатмалар. әзер., кереш сүз авт. Ф. Фәйзуллина]. Казан: Татар. кит. нәшр., 2013. Б. 89.

[3] «Doğan Güneş» – Истанбулда чыккан дини, мөстәкыйль сәяси, гыйльми, әхлакый атналык газета. Мәхмүт Җәүдәт Сезернең башъязарлыгында 1947 елның август аеннан 1948 март аена кадәр җәмгысы 10 сан күләмендә чыгарыла.

[4] Mahmud Cevdet. Hoş geldiniz. Doğan Güneş. 17 Eylül 1947 5. Sayı 72. Sayfa.

*Җаруллаһ турында. Һиндестанда яшәве турында хәбәрне алганнан соң остазның кисәк кенә мәмләкәтебезгә килеп төшүе барыбызны да сөендерде. Үзенә: «Хуш килдегез»,– дибез. Фәкать остазның җиребезгә аяк басар-басмас газеталарга әйткәннәренә бакылса, ул динебезнең без ияләнгән берникадәр кагыйдә һәм кыйммәтләрен бөтен-бөтен үзгәртергә тели. Боларныңниләрдән гыйбарәт булулары әлегә билгеле түгел! Моның белән бергә, «сәләфия» гыйбарәсе белән консерватив мөселманнарның бәйләнгән нигезләрдән аерылганлыгы күзгә атыла. Муса Җаруллаһның Җәмалетдин Әфганинекенә бик охшаш күренгән хәрәкәтле бер фикерләү ирегe һәм хәрәкәте бар. Бөтен йөрәгебез белән ялварабыз ки: бу охшашлык тышкы гына булып калсын һәм тудырачак нәтиҗәләр мөселманлыкка, мәмләкәтебезгә хәерле нәтиҗәләр булсын. Бары тик биредә һәр мөселманның, аеруча һәр мөселман төрекнең зур кызыксыну белән өйрәнергә тырышкан нокталар бар ки, боларның башында остазның гакыйдәсенең чикләредер. Остазга бу гакыйдәсен безгә анык чикләр белән белдерүен үтенәбез. Иң белдеклелек белән очрашуыбыз аркасында безне озын заман көттермәячәгенә инанабыз. Әгәр остаз Муса Җаруллаһ узган саныбызда бер мәкаләсе чыккан Хаҗи Хәмди Әлазами белән Багдадтагы мөсафирлеге чагында дәвамлы мөнәкашә бәхәсләргә юл ачкан карашларын сакласа, димәк ки үзе белән мондый бер мөнәкашә безнең өчен дә әйләнеп узу мөмкин булмаган бер нәрсә булачак! Бу хәлдә һәрнәрсәдән әүвәл остаздан үтенәбез:*

*Матуридиләр белән Әшгариләрдән кайларда аерылсагыз, бу аерылган нокталарның чикләрен билгеләвегезне телибез. Бу бер.*

*Янә остаздан үтенәбез:*

*Мөҗтәһидлек дәгъвасында булсагыз, бу мәшһүр «Яратучы һәр йөз ел башына бу өммәткә динен җиңеләйтәчәк кемсәләр җибәрәчәк!» хәдис шәрифне ишарә кылган шәхес булуыгызга инанасызмы? Бу очракта «мөҗәддид»лек белән «иҗтиһад»ның янә тулы чикләрен [белергә] телибез. Бу да – ике!*

*Әлегә бу кадәрен җитәрлек күреп, сезгә тиз шифалар сорыйбыз, газиз остаз!*»

«Doğan Güneş» журналының шул ук санында шул ук автор «Büyük Türk Bilgini Musa Carullah ile Bir Karşılaşma»[1] («Бөек төрек галиме Муса Җаруллаh белән бер очрашу») исемле тагын бер мәкалә бастырган: «*Истанбулның һәм бөтен Төркиянең артта калган бердәнбер фикъһы белгече Хөсрәү әфәнде хәзрәтләренең дәрәҗәле шәкертләреннән Габдулхәлим белән бергә «Гураба» хастаханәсенең иске бинасына кердек. Күп кешеле бер палатаның урталарында куелган бер ятакта бер шималь төркенең бөтен асыл чалымнарын йөзендә саклаган бөек төрек галимен утырып торган хәлендә таптык. Китәргә әзерләнгән ике кунак белән ахырына якынлашкан бер сөйләшүне тәмамлыйлар иде.*

*Утырдык һәм бераздан сөйләшә башладык. Бу – тормышымда беренче очрашу. Фәкать үземне остазга никадәр якын тоям!.. Килгәндә дә, киткәндә дә эчемне тутырган дулкын-дулкын кайгы (тавышы) эчендә үземнән кичкән бер хәлдә идем. Һәр дәвердә золым вә изү газаплары эчендә әвәләнгән бу илнең һәр заманнан артык гыйлемгә һәм гыйлем адәменә мохтаҗ булуы бу көннәрдә бөтен дөнья мөселманнарының ихтирам һәм яратуын казанган бер төрек галименең ят илләрдә интегүләренә һич ризалыгы юк.*

*Остазга «Хуш килдегез!» һәм «Узышлы булсын!» дигәннән соң, әңгәмәбезне дәвам иттек. Башта үзләренә өченче көн газеталарда һәм бу арада Тасвир газетасында чыккан сүзләреннән бу җөмләне ишеттердек:*

*– «Бөтен башка мөселман милләтләренең бердәнбер котылу юлы бүген Төрек Җөмһүриятенең тоткан юлны тотудыр!» Бу җөмлә дидем, чыннан да сезнең җөмләгезме?*

*– Әйе, – дип җавап бирделәр.*

*– Бу хәлдә, дидем, моның тагын да ачыграк бер шәкелдә аңлатылуын, яхшырак яктыртылуын үтенәчәк идем.*

*Мондый җавап бирделәр:*

---

[1] Mahmud Cevdet. Büyük Türk Bilgini Musa Carullah ile Bir Karşılaşma. Doğan Güneş. 17 Eylül 1947 5. Sayı 76. Sayfa.

*– Бу җөмлә белән мөстәкыйль бер дәүләт буларак тотылган юлдан, сәяси бәйсезлек һәм хакимият юлыннан башка бер юлны күздә тотмадым.*

*Каршы чыктым:*

*– Болай булганда, ул чакта «сәяси бәйсезлек бер милләтнең котылуы өчен җитәрлек була» кебек бер дәгъвага киләбез ки, моны исбат итү мәҗбүриятендәбез.*

*– Юк, дип өстәп куйдылар, алай түгел: Бу бәйсезлек сәяси булган кадәр әхлакый, хокукый, дини, гаиләви, әдәби һәм гамәлдәге һәр иҗтимагый оешмаларны катнаштырган һәм бөтен иҗтимагый вакыйгаларны колачлаган бер бәйсезлек булачак.*

*Бу ноктада без дә остазга шул ук фикерне уртаклаштык. Фәкать биредә яңа бер кыенлык килеп чыкты: Бу бәйсезлеккә ирешүнең юлы нинди? Һәм боларның кайсысыннан хәрәкәт итү тиешле? Биредә төрле-төрле сукмаклар бар ки, Муса Җаруллаһ остазыбыз бу кыенлыкны төеннәрен хәл иткән һәм җиңеллек, иркенлек биргән бер тылсым белән әйттеләр: «Коръәни кәрим!»*

*Коръәни кәрим – бу бөек һәм катлаулы кыенлыкларның төеннәрен чишкән, йозакларны берәм-берәм ачкан мөкатдәс тылсымның исемедер. Бу мөкатдәс тылсым бөтен җир йөзенең бердәнбер милләтләр төркеменең кулындадыр: мөселманнар.*

*Фәкать биредә янә бер киртәгә юлыгабыз:*

*Коръәни кәрим бер үк хөкемнәрен әлегә кадәр бары тик динебездә 73 төрле аңлашылуы мәйданга чыккан. Боларның кайсысы дөрес, кайсысы дөрес түгел, шуны беләсе иде? Менә бу ноктада остаз белән мөнәкашә юлына чыктык.*

*Кирәк схоластика мантыйгын, кирәк методологияне, асыл башлангычлары өстенә кагылган бу мөнәкашәнең тәфсилятын киләчәк санга калдырып, бу мәкаләбезне биредә өзәбез.*

*Бу чарадан файдаланып илнең сәяси һәм гыйльми компетентлыларының игътибарларын бер ноктага юнәлдерергә телим: «Иҗтимагый мөгаййәният» билгесез фаразыясенә сукырларча багланудан ваз кичсә, Бугленың, Дэвиның, Маусс*

*һәм башкаларның куллары белән ачылган яңа офыкларга күз салыйк.*

*Бу булган кадәр киң һәм ахырсыз үсеш һәм югарыга ашу тизлеген вәгъдә иткән офыкларда инсани кыйммәтләрнең, ягъни шәхсият сахибы гыйлем адәмнәренең җәмгыятьләрнең барлыкка килүе һәм камилләшүендә зур өлешен исәпкә алырга мәҗбүрбез. Бу хәлдә Муса Җаруллаһ кебек, Мостафа Сабри кебек ихлас эчкерсез төрек галимнәренең бөтен дөнья кимәлендәге кыйммәтләренә аркан борыла алмыйбыз. Кулыбыздагы төрек кыйммәтләре – бөтен мөселман дөньясына юлбашчылык итү тарихи ролебезне кабат безгә алдыра алачак дини бер оешма төзүгә яраклы, хәтта җитә килә ала. Хәзер үк Аллаһ төрек милләтен үткәннең хаталарыннан коткаруга һәм күп газап чиктергән тәҗрибәләрдән гыйбрәт алуга ирешергә язсын!*»

Ниһаять, сентябрь аенда чыккан «Selâmet» журналында да баш мөхәррир Гомәр Рыза Догрул әфәнде «Musa Carullah» («Муса Җаруллаһ») мәкаләсендә Муса әфәнденең Истанбулга килүенә шатлануын яшерә алмыйча болай дип язган: «*Утыз биш ел элек азатлыкка ирешү һәм көрәш хәятенә атылган заманыбызда ул инде ислам галәмен яулаган саф һәм шәрәфле бер шөһрәт иясе иде. Ислам галәменең гәрчә һәр тарафында голәма бар иде, фәкать ислам галәме голәмагә түгел, мөтәфәккирләргә мохтаҗ иде. Голәмаләр һәрнәрсәне белә ала, һәм ислам голәмасе, чыннан да, ислам гыйлемнәренең һәммәсен иң тирән катламнарыннан башлап колачлыйлар иде. Фәкать ислам галәменең ихтыяҗы бары тик белү түгел, күбрәк юл табу һәм юлга чыгу иде. Бездәге голәма исә, бары тик белүләре белән чикләнгән булулары сәбәпле, юл күрсәтүдән гаҗиз иделәр. Аларга күрә юл күрсәтүнең, хәтта, кирәге дә юк иде. Чөнки юл билгеле иде һәм мәгълүм булган юл буйлап барудан башка эшләнәсе бер эш юк иде. Әмма заман үзгәргән иде, гыйлем үзгәргән иде, дөнья үзгәргән иде, корал үзгәргән иде һәм көрәш кыенлашкан иде. Ислам милләтләре берәм-берәм егыла торып, хөррият һәм мөстәкыйльлегеннән мәхрүм булалар иде. Исламиятнең тәрәккыйга киртә булуы*

*турында сүз йөртелә иде һәм ислам милләтләре артта калганлыкның, фанатизмның гәүдәләнеше буларак тамгаланалар иде. Әмма голәманең боларда һич кайгысы юк иде. [аларның уйлавынча] Бу диннең язмышы сахибенең [Аллаһның] кулында иде, ул теләсә аны күтәрер иде. Ягъни бер кемсәнең бу эшкә алынуы кирәк тә түгел иде. Хәтта андый кеше табылып, аның бу эшкә алынуы [голәмаләр күзлегеннән караганда] куелган чикләрне белергә теләмәвеннән башка берни түгел иде. Болар [голәмаләр] шундый иделәр, әле дә шундыйлар булып калалар.*

*Күп шөкер – Муса Җаруллаһ куелган чикләрне белергә теләмәгәннәрнең берсе иде һәм шуңа күрә фанатизм һәм җаһиллек белән аяусыз төстә көрәште. Фанатизм һәм җаһиллектән котылган ислам галәменең күтәреләчәгенә инанып, рухының бөтен кызулыгы белән ислам галәмен яктыртырга һәм юл күрсәтергә тырышты һәм күп шөкерләр казанды.*

*Муса Җаруллаһ – дәверебезнең йөзен агарткан ислам мөтәфәккирләреннән берседер. Соңгы вакытларда Мисырда Мәхмәт Габдүһ, Һиндестанда Икъбал, Әфганстанда Сәед Җәмалетдин, һәм, күп шөкер, төрек илләрендә Муса Җаруллаһ җитеште. Аның исламны аңлавында нәкъ бүгенге көн өчен [кирәкле булган] сиземләү һәм бүгенге көннең ихтыяҗлары хакимлек итә иде. Чөнки яшәгән дәверенең белемен алган һәм исламиятне шул белемнең йөреше һәм сиземләве белән колачлады. Исламиятне бүгеннең рухын яктырта торган илһам чишмәсе буларак мөселманнарга яңадан тапшырды.*

*Хәятенең соңгы 25 елын турыдан-туры ислам галәменең бөтене белән һәм ислам галәменең Мисыр, Һиндестан, Индонезия һәм Чин кебек һәр парчасы белән йөзгә-йөз каршылашкан Муса Җаруллаһ бүген дөньяның иң бахтияр адәмедер. Чөнки хәятендә ислам галәменең коточкыч дәрәҗәдә түбән төшүен күргән кебек, үз тырышлыгының кушылуы белән һәм алып барган көрәшенең кызулыгы белән аның, күп шөкер, күтәрелеш чорына керүен дә күрү һәм алга таба бу күтәрелеш дәверенең бер каршылыкка юлыкмыйча үсеп китәчәгенә*

*имин булу кебек нык һәм какшамас бер инану эчендә яшәү мөмкинлеген казанган иде.*

*Идеал күзе белән караганда*[1] *бу кадәр бәхетле ителгән бер кеше буларак, Муса Җаруллаһ бөтен ислам галәме өчен югары бер үрнәктер. Чөнки бүгенге ислам галәме аның кебек күтәренке югары рухлы, киң акыллы, мөтәфәккир мөҗаһидләрнең*[2] *әсәредер. Ислам галәме аның көндәшләре тарафыннан дәгъва ителгән зәррә кадәр эшләрдән, зәррә кадәр хәрәкәтләрдән [нидер] көтсә иде, һичбер вакыт бүгенге манзараны күрмәс һәм бүгенге күтәрелешкә ирешмәс иде, бәлки мәңге бакый колония буларак калыр иде дә, колониализм аның гәүдәсен һәм табигый байлыкларын умырып алып кимергән кебек, рухын да умырып алып кимерер иде.*

*Фәкать Идеал күзе белән караганда бу кадәр бәхетле ителгән Муса Җаруллаһ шәхси хәяте карашыннан иң бәхетсез кешедер. Чөнки егерме-утыз елдыр ишеннән вә бала-чагасыннан мәхрүмдер. Егерме-утыз елдыр үзенең йортыннан мәхрүмдер. Егерме-утыз елдыр дусларыннан һәм якташларыннан мәхрүмдер. Бөтен бу мәхрумиятләргә фәкать идеалга хезмәттә булуы хакына сабыр иткән. Күп шөкер ки, идеал аңа хыянәт итмәгән һәм аңа тормышта иң зур юанычны биргән.*

*Бу каһарман йөрәкле бөек төрек вә ислам мөтәфәккиренең илебезгә килүен иң тирән сөенеч белән каршылап, арабызда бик яхшы көннәр кичерүен үтенәбез.*

*Гомәр Рыза Догрул»*[3].

Муса әфәнденең исеме Гаяз Исхакый тарафыннан икенче мәртәбә 1947 елның 23 октябрендә язылган мәктүптә телгә

[1] Ул заманда Төркиядә хөкүмәтнең дингә каршы сәясәт үткәргән булуын күздә тотканда, Догрулның «идеал күзе белән караганда» дигән гыйбарәсен «Аллаһ күзе белән караганда» дип аңлау дөрес булыр.

[2] мөҗаһид – тырышып эш итүче; үзенең рухына, акылына һәм белеменә таянып җиһад кыйлучы.

[3] Ömer Rıza Doğrul. Musa Carullah. Selâmet. 26 Eylül 1947.

алына: «*Муса әфәнде хастаханәдән чыккан. Йөри башлаган. Миңа да килеп киткән. Өйдә булмаган чагым тугры килгән*», диелә бу хатта[1].

Югарыда китерелгән мәгълүматлардан күренгәнчә, Муса Җаруллаһ 1947 елның башын Һиндестанда, күпмедер өлешен Мисырда, һәм, мөгаен, октябрьдән башлап, соңгы айларын Төркиядә үткәргән булып чыга.

Истанбулда чагында Муса әфәнде Йосыф Уралгирәйгә мәктүп юллый. Анда түбәндәгеләрне яза: «*Суык көннәрнең соңына кадәр мин, бәлки, Истанбулда калырмын. Сәяхәтемнең җиһәтләре бу вакытка кадәр миңа билгеле түгел. Норвегиядә Хаммерфест тарафларына хәрәкәт хыяллары да күңелемдә юк түгелдер. Ул җирләрнең мәдәниятен янә күрә алу теләге күңелемдә саклана. Ул тарафларга хәрәкәтем турында фикерегезне языгыз. Авыр сандыклар эчендә зур күләмдә кыйммәтле китапларым җыелды. Боларны кая җибәрим? Хәятем соңгы минутларына якынлашты. Вафат итсәм, кыска һәм туры юлдан каберемә иңәр исәм, китапларым заигъ булыр дип куркам. Кабул итсәгез сезгә, Финляндия мөселманнарына, әманәт итим. Яхшы бер көтепханә булыр. Балаларым да бәлки бер көн китапларымны күрерләр. Петербургтагы көтепханәм Академия наук көтепханәсендә калды. Бу китапларым да ул якларга якын булса, бәлки соңыннан һәммәсе бер җирдә тупланыр.*

*«Мәсахиф әл-әмсар» исемле кечкенә исә дә иншаллаһ гаять мөһим бер рисаләм чыгачак. Иншаллаһ Истанбулда бастырырмын. Игелекле Финляндия мөселманнарына бүләк итәрмен. 38 ел элек басылган китабымны тәмамлаячак эчтәлекледер иншаллаһ. 18 еллык сәяхәтемне тәмамларга телим. Фәкать сизенүемә күрә, бу мөмкин булмаячак. Башта Һаммерфест шәһәренә бару теләге калебемдә яши. Виза ала алсам, Аллаһ эстәсә, шунда китәчәкмен. Дини, гыйльми бер өметем бар. «Рузә» исемле китабым бәлки кулыгызда бардыр. Ул китабымны иншаллаһ тәмамлармын. Башка кешеләр назарында бу әсәрнең әһәмияте юктыр. Булса да*

[1] Исхаков. Күрс. кит., б.100.

*минем назарымда моның әһәмияте бик зур. Ястү намазы хакында фәкыйһләрнең ихтиляфлары зурдыр. Бөек остаз әл-Мәрҗани хәзрәтләренең китабы бер Болгар җирендә бер намаз хакында иде. Минем китабым исә бөтен җир йөзендә бөтен намазлар хакындадыр. Эшләрем файдасыз булмады. Тәнем, вөҗүдем зәгыйфь исә дә калебем, мием, Аллаһка хәмед булсын, саулыклыдыр. Кадер мәсьәләсе хакында кыйммәтле, файдалы, кечкенә бер рисалә язган идем. Истанбул журналларында басылды. Аллаһка күп шөкер, 38 ел элек басылган бер рисаләдер»*[1].

Бу хаттан аңлашылганча, Муса әфәнде Норвегиягә барырга планнар кора, Истанбулда да, кимендә, кыш айлары үтеп киткәнче калырга ниятләгән була. Шуңа күрә ул Әнкарага да барып килергә җай таба: 1947 елның 8 ноябрендә язылган хатында Гаяз әфәнде кызы Сәгадәт ханыма болай дип язган: «*Муса әфәнде бүген Әнкарага китәчәк иде. Бәлки, киткәндер, бәлки, китмәгәндер. Китсә, сине эзләп табар. Вакытың булса, үзенә бер кайнар шурпа ашат. Ул хәзер бик мескинләнгән. Бик зәгыйфь, шайаны шәфкать*[2] *бер хәлгә килгән. Бөтен гомерен ислам галәмен ислях итәм дип йөреп дә, бүген үләр алдыннан ислам дөньясында утырачак бер йир таба алмау, үлсә, үзенә ислам галәмендә мазарлык ике метрлык бер тупрак парчасы тәэмин итә алмау – бик зур фаҗигадер. Әлбәттә, үзенең дә хатасы булгандыр. Хатасыз кем бар?..*»[3].

Ноябрьнең 12 сендә язган хатында Исхакый кызына борчылып: «*Муса әфәнде сине эзләп таптымы? Юлда йөри-йөри үлеп калмаса ярый инде. Бик зәгыйфьләнгән*»,– дип яза[4].

Ул арада Муса әфәнде, чыннан да, Әнкарада була. Бу хакта аның белән 1909 елда «Хөсәения»дә булган вакыйгалардан бирле таныш Баттал-Таймас әфәнденең хатирәләреннән беләбез: «*1947 елның ноябрь ае башларында Муса әфәнде Әнкарага килде. Аның киләчәге турында алдан ук хәбәрле*

[1] Uralgiray. Mektuplar, s.19.
[2] шайан-ы шәфкать – шәфкатькә лаек.
[3] Исхаков. Күрс. кит., б. 102.
[4] Исхаков. Күрс. кит., б. 104.

*булуыбыздан, үзен якташыбыз булган сәүдәгәр Гали Төмән белән берлектә вокзалда каршыладык. Остазны көчкә таныдым: шулкадәр бетешкән хәлдә һәм бик ябык иде. Автомобиль белән урта сыйныфлы «Айдын» кунакханәсенә китердек. Иртәнге ашны бездә ашадык. Авыру һәм бик зәгыйфь булуына карамастан, элеккечә чәй эчүе һич үзгәрмәгән иде. 37 ел элек Оренбургта күргәнем чәй эчү рәвешен ул көнне дә нәкъ шундый итеп күрдем. Шул арада: «Тагын эчәбезме?» – дип сораганымда, көр тавыш белән: «Эчәбез әле!» – дигәнен әле дә ишеткән кебек булам.*

*Торган кунакханәсе безнең өйгә бик якын булганга, гадәттә һәр көн иртән һәм икенде чәйләрен бездә эчә идек. Муса Җаруллаһ әфәндегә кагылышлы мәкаләләремне язганда кайбер җитешмәгән урыннарны тулыландыру өчен кирәкле мәгълүматны Истанбулдан, Муса әфәндедән бер дустым аркылы ала идем. Әнкарага килүе дә бу йөздән яхшы булды: тәмамлый торган кайбер мәгълүматны нәкъ әнә шул чәй мәҗлесләре дәвамында турыдан-туры остазның үзеннән өйрәндем һәм ул вакытка кадәр язылып беткән өлешләрне үзенә укыдым һәм җитешсезлекләрен тулыландыруын һәм ялгышлары булса, төзәтүен үтендем. Бу үтенечемне кабул итте һәм бик аз төзәтмәләр кертте. Шәһәрдә кылган кайбер зиярәтләре вакытында да үзенә юлдашлык иттем.*

*16 ноябрьдә якташларыбыздан бөгелмәле Миңлехан әфәнде безне акшам ашына чакырган иде. Ашта башка якташларыбыз да бар иде. Дәүләт консерваториясе укытучыларыннан Мидхәт Акалтан миңа Финляндиядән Халидә Вафа ханымнан җибәрелгән язмаларга карап кәманда[1] Казан милли көйләрен уйнады. Җыр җырлаганнар да булды. Хәзрәтебезнең бик күңеле булды, ачылып китте, сөенеп утырды. Әнкарадагы башка якташларыбыз үзенә әлләни игътибар бирмәделәр.*

*Муса әфәнде Әнкарада 8 ноябрьдән 17 ноябрьгә кадәр калды. Бу соңгы көндә 19:20-дә кузгалып киткән экспресс поезды белән үзен Истанбулга озаттык. 27 ноябрь 1947 тарихы*

[1] кәман – скрипка.

*белән миңа Истанбулдан бер мәктүп язып җибәрү нәзакәтендә булды. Бу шактый озын хатта хатыным белән миңа һәм үзе белән аралашкан башка якташларыбызга сәлам һәм шөкерләр юллаганнан соң арада түбәндәгеләрне дә язган иде:*

*«Бәрадәр Абдуллаһ бәй Баттал-Таймас әфәнде, сезә минәл-кадим сәдакатьле дуслыгым, ихтирамым бар иде. Шу дефа да җәнабыңызны һәр җиһәт илә таныдым. Садакатымда, ихтирамымда исабәтеми аңладым, мәмнүн улдым. Өслүбеңездә фәсахәтеңези, бәлягатеңези белер идем, ләкин кувәи шигърияңездән хәбәрем юк иде. Сәлис шәһл-и мөмтәни әшгарыңызи ишетеп гаять мәмнүн олдум… Әнкара бәрадәрләренең мәҗлесләрендә гүзәл әдәбеңези, васигъ әхлакыңызи күреп мәмнүн олдум, Сезә рәхмәт!*

*Шу соң сәнәдә хәятем әхвәл (куркыныч хәлләр) эчендә, уфак-бөек авырлыклар эчендә кичте. Бүген тарлыкта-фәкыйрьлектә, юклыкта калмактан куркам.*

*Классикларны тәрҗемә куәте галәл-кәмал сездәдер. Галиба уйлә хезмәтләр илә мин мәшгуль уламам. «Мәсәррәт» кеби түбән дәрәҗәле отельләр иштигаль йире оламаз; уйку бүлмәләредер: нур юк, хәтта иң уфак зарурәтләре юк. Әлемдә сәфәр паралары булунса иде, йә Каһирә, йә Финлянд тарафларына китәр идем»*[1].

Габдулла Баттал-Таймас Муса әфәнде белән соңгы мәртәбә 1948 елның җәендә Әнкарадан Истанбулга ялга килгән көннәрендә күрешә: «*Муса әфәнде 1947–1948 кышын Истанбулда кичерде. Истанбулдагы казанлылардан ярлысы да, барлыклысы да үзе белән бик кызыксынмады. 48 җәендә ял итәр өчен Әнкарадан Истанбулга килгәнемдә үзен тагын бер мәртәбә күргән идем. Җагаоглунда «Җөмһүрият» газетасы матбагасына якын бер җирдә бер мөфтинең өендә мосафир иде…*»[2]

Димәк, Әнкарадан Муса әфәнде янә Истанбулга кайта. Гаяз Исхакыйның язуларына караганда, биредә остаз күптәнге дуслары һәм фикердәшләре белән күрешеп-аралашып торган.

---

[1] Battal-Taymas, A. Musa Carullah Bigi. Kişiliği, fikir hayatı ve eserleri. Kazanlı Türk Meşhurlarından II. İstanbul, 1958. Б. 51–52.

[2] Battal-Taymas. Күрс. хезм., б.54.

Алар арасында Исхакый үзе, Садри Максуди, Зәки Вәлиди Тоган, Госман Токумбит һәм башкалар булалар. Мәсәлән, Зәки Вәлиди Тоганның 1948 елга караган хатирәләрендә: «*Муса Җаруллаһ... Истанбулга килеп, алты ай дәвамында минем өемдә кунак булды*»,– дип язып калдырган.

Гаяз әфәнде Исхакыйның хатлары Муса Җаруллаһның Төркиядә үткәргән көннәре турында бәһасез мәгълүмат чыганагы булып тора. Мәсәлән, 1947 елның 4 декабрендә язылган хатта Исхакый кызына шундый хәбәр ирештерә: «*Муса әфәнде Госман Токумбиткә*[1] *Әрәнкөйә ташынды*»[2], ә бер атна узгач, чираттагы хатында: «*Муса әфәнде сау-сәламәт. Кышны монда үткәрәм, ди*»,– дип яза[3].

Декабрьнең 26-сында язылган мәктүбендә мондый сүзләр бар: «*Муса әфәндене͡ң зәгыйфьлеге, минемчә, хасталыкдан фазлан*[4] *картлыктан килә. Хәзер: «Күзлекләрем картайган. Күзем начар күрә башлады. Күзлекләрне үзгәртергә кирәк»,– ди. Бәлки, бу да тугрыдыр. Әмма күзләре дә яшәймәгәндер. Синең һәдияңне*[5] *алырмы, белмим. Ул бит ярлы тәкәббер*»[6].

---

[1] Госман Токумбит – татар милли азатлык хәрәкәте вәкиле. Санкт-Петербург университетында укыганда 1913 елда Петербург мөселман хәйрия җәмгыяте тарафыннан каралган Габдулла Тукай исемендәге стипендия казана (Биктимирова Т. А. Ступени образования до Сорбонны. Казань, Алма-Лит, 2003. Б.15.). 1917 елда Мәскәүдә һәм Петроградта үткәрелгән мөселман корылтайлары көннәрендә Муса Җаруллаһ белән таныша. 1918 елда Идел-Урал Штатын төзүчеләрнең берсе. Большевиклар хакимиятеннән качып, Төркиягә китә. Төркиянең Советлар берлегендәге илчесе вазифаларын башкарган. 1923 елда, шымчылыкта гаепләнеп, СССРдан сөрелә.

[2] Исхаков. Күрс. кит., б. 107. Хатлардан аңлашылганча, Муса әфәндене үзендә торырга Садри Максуди да чакырган булган, тик Муса әфәнде яхшысынмаган. Соңрак Муса әфәндене үз өенә Һидаять исемле бер кеше алган. Аннан соң Зәки Вәлиди Тоганда да торганы мәгълүм булды.

[3] Исхаков. Күрс. кит., б. 108.

[4] хасталыкдан фазлан – авырудан битәр.

[5] һәдия – бүләк.

[6] Исхаков. Күрс. кит., б. 109.

Гаяз Исхакый мәктүбләрендә Муса әфәнденең кат-кат искә алынган зәгыйфьлеге тиктомалдан түгел – Истанбулда аның «Гораба» хастаханәсендә ятып дәваланган булуы да мәгълүм.

Алга таба язылган хатлардан Муса әфәнденең бер мәлдә Финляндиягә китәргә ниятләве турында белә алабыз. Бу теләгенең сәбәбен исә башка бер хаттан чамалап була: 1948 елның 22 гыйнварында язылган хатта Муса әфәндегә Төркиядә торырга нибары өч ай вакыт бирелгән булуы турында хәбәр бар. Шул ук вакытта Сүриягә китү нияте дә булган, тик 30 нчы еллардагы хәл кабатланып, аңа бу юлы да виза бирелмәгән. 1948 елның 6нчы апрелендә язылган хатта болай диелә: «*Муса әфәндене кичә Һидаять [...] хастаханәсенә йирләштерде һәм дә Муса әфәнденең Һиндестанданмы, Русиядән үкме алып килгән шикәрләрен, хезмәтчегә чәйлек биреп, Муса әфәндегә: «Докторлар кушды, башкача булмый»,– дип юдырткан. Юынып чыккач, Муса әфәнде танымаслык дәрәҗәдә үзгәрде, ди. Сыйххәте бер дә шәп түгел. Акрын-акрын гына сүнүгә бара шикелле. Нәфес тарлыгы*[1] *бик көчле. Хәле бер дә юк. Өй эчендә бик авырлык берлә йөри ала*»[2].

Бераз соңрак язылган хатында Муса әфәнденең хәле турында Исхакый болай ди: «*Муса әфәнденең хәле шәпдән түгел. Тавышы бик үзгәргән. Теле бәйләнә башлаган. Кайбер сүзләрне бик авыр әйтә ала. Иштиһасы*[3] *да юк. Ул акрын-акрын гына юлчылыкка хәзерләнә*»[4].

Шул ук апрель аеның 28-ендә язган хатында Гаяз әфәнде, хастаханәгә барып, Муса Җаруллаһның хәлен белешүе турында яза: «*Муса әфәндене пазар көне*[5] *барып күрдем. Тагы күзен ачкан, теле чыккан, йөзенә нур кергән. Тазара башлаган. Эшләр шулай китсә, Мексикада күрмәгән шәһәрләрем бар, шунда китәм, дия башлаячак. Һидаять үзенә ике көн-*

[1] нәфес тарлыгы – тын кысылуы.

[2] Исхаков. Күрс. кит., б. 124.

[3] иштиһа – аппетит.

[4] Исхаков. Күрс. кит., б. 127.

[5] пазар көне – якшәмбе.

*дә бер аш пешереп, илтеп ашата. Хастаханә ашына канәгатьләнә алмый»*[1].

Төркиядә яшәгән санаулы айларда Муса әфәндегә карата бик тә зур әшәкелек эшләнә. Бу вакыйга турында Исхакыйның 1948 елның 21 августында язылган хаттан белеп була: *«Бу атна эчендә безнең мондагы агай-эне мәшгуль иткән мәсьәлә Муса әфәнде хакында Батталның бик чиркин*[2] *язулары булды. Муса әфәндегә дустлары төрек тәбәгалеге*[3] *алып бирү берлә уграшалар иде*[4]*. Үзе дә шуны бик тели иде. Шул хакда полис тәхкыйкатен*[5] *ясап ята иде. Баттал, «Тасвир» гәзитәсендә Йосыф Акчураны дегенерат, алколик*[6] *баласы, идеалсыз адәм дип, әнваг тәхкыйрьләрдән соң Муса әфәндене кулга алып, тетеп салды. Муса әфәндене большевик агенты итеп, бер алколикның баласы, сәяси авантюрист итеп чыгарды. Бу бөтен колониягә*[7] *фәукылгадә*[8] *начар тәэсир ясады. Муса әфәнде, мескин, хасталанды, берничә көн ашый алмады. Көне-төне аглады, диләр. Без хәзер шул начар тәэсирләрне азалтыр өчен колониядән имзалар туплап, матбугатка бирдек. Мескингә тәбәгалеген бирмәү ихтималлары бар. Үзе болай да көннән-көн зәгыйфьләнә, ябыга бара. Элекке кебек Яшелкөй мөфтисенең өендә мөсафир булып яши. Үзен бик карыйлар»*[9].

Бу хатта сурәтләнгән күңелсез хәлләр татар җәмәгатьчелеге тарафыннан игътибарсыз калдырылмый һәм, чираттагы бер хаттан аңлашылганча, мәсьәлә хәл ителеп, нокта куела: *«Муса әфәнде мәсьәләсен берничә төрек мөхәрриренә мә-*

[1] Исхаков. Күрс. кит., б. 127.

[2] чиркин – әшәке, яман.

[3] тәбәгалек – гражданлык; гражданство.

[4] уграшалар иде – шөгыльләнәләр иде.

[5] полис тәкыйкате – полициягә тапшырылырга тиешле рәсми кәгазьләр.

[6] алколик – алкоголик.

[7] колония – Г. Исхакый бу сүз белән Истанбулдагы татар җәмәгатьчелеген атый.

[8] фәукылгадә – гадәттән тыш.

[9] Исхаков. Күрс. кит., б. 143.

*каләләр язарга риҗа итеп*[1] *капатдык. Зәки Вәлидиләр карышып, тагы чуалтмасалар ярый. Шәрык зиһниятендәге*[2] *кешеләр берлә эш итү бик авыр. Аларның берсендә дә самимият юк. Әллә нинди безнең хәтергә килмәгән планлар ташыйлар. Муса әфәнде дә монда мөстәсна*[3] *түгел. Без уны сәяси мөҗадәлә сәхнәсендә йире калмаган, иткән хезмәтләре өчен хөрмәткә лаек, хасталыгы, картлыгы, горбәте берлә*[4] *шәфкать-мәрхәмәткә мохтаҗ дип карыймыз. Вә шул җәһәтдән кулдан килгән ярдәмне итәргә маташамыз»*[5].

Чираттагы хатларның берсеннән аңлашылганча, Муса әфәндегә Төркия гражданлыгы бирелә. Димәк, Баттал-Таймас тарафыннан аңа ягылган мыскыллы ялалар нәтиҗәсез булып чыгалар[6].

---

[1] риҗа итеп – үтенеп.

[2] зиһният – фикерләү рәвеше, менталитет.

[3] мөстәсна – чыгарма.

[4] горбәте берлә – читтә ялгыз булуы сәбәпле.

[5] Исхаков, М. Г. Күрсәтелгән китап, б. 145–146.

[6] Г. Батталның бу кыйлмышларын һич тә аңларлык түгел, чөнки 1921 елның сентябрендә Муса әфәнде әлеге мәхлүкъка ярдәм кулын сузып, аны, Кронштадт аркылы Финляндиягә чыгарып, большевиклар эзәрлекләвеннән коткарган кеше була. (Бу турыда кара: http://sombel.ru/category/fenni-mekaleler-feride-gaffarova (23.05.2019 каралды).

# Бишенче фасыл.
# Гомеренең соңгы елы һәм вафаты

## Төркиядән китүенең сәбәбе – Коръән тәрҗемәсе

Бер уйлаганда, Төркия гражданлыгын алганнан соң, Муса әфәнде күңеленә якын, дус-ишләре күп булган бу илдә рәхәтләнеп яшәп кала алыр иде кебек. Бәлки соңгы сулышын да бу бәрәкәтле җирдә алган булыр иде. Әмма юк: гражданлык алыр-алмас борын Муса әфәнде үзенә чит ил паспортын да хәстәрли башлый. Ул аңа Мисырга барыр өчен кирәк була.

Мисырга бару турындагы бу ниятләрен без әле алга таба искә төшерербез, ә хәзер галим Төркиядән киткән датаны тәгаенләү мәсьәләсенә туктап алыйк. Гаяз Исхакый аның турында сүзне болай тота: «*Муса әфәнде көннән-көн сүнә килә. Без уны һичбер җибәрү тарафында түгелмез, әмма бик гыйнадчы*[1]»[2].

Ягъни Муса әфәнденең Мисырга китү турындагы карары катгый булган. Әмма нидән? Ни өчен инде картаеп, сәламәтлеге нык какшаган Муса әфәнде Мисыр хәтле еракка барырга ният иткән? Эзләнә торгач, бу сорауга да җавап табылды.

Бу урында Муса Бигиевнең соңгы елларында күргәннәрен бәян итүне бераз кичектереп, сүз уңае белән түбәндәгене дә белдерәсе килә. Чынлыкта, Муса әфәнде гомеренең соңгы елы, ягъни 1948-нең ноябрь аеннан 1949 елның октябрь аена кадәр вакыт аның яңадан Коръән тәрҗемәсен бастырып чыгарыр өчен куйган тырышлык һәм күргән мәшәкатьләр эчендә үтә. Аның Коръәнгә кагылышлы гыйльми хезмәтләренең иң югары ноктасын Изге китапның 1912 елда тәмамланган татар теленә тәрҗемәсе тәшкил итә. Бу тәрҗемәне бастырып дөньяга чыгару өмете нәкъ менә 1948 елда, Муса әфәнде Истан-

[1] гыйнадчы – үзсүзле.

[2] Исхаков. Күрс. кит., б.161.

булда яшәгән вакытта яңадан уяна. Биредә ул Җамал Кутай[1] исемле эшлекле һәм диндар бер нашир белән таныша. Җамал Кутай ул вакытта «Hakka Doğru» белән «Millet» исемле журналлар чыгарган мөхәррир була. Муса Җаруллаһны бик хөрмәт иткән бу кеше, Коръән тәрҗемәсен бастыру мәсьәләсен үзе кузгатып, Муса Җаруллаһка аны үзенең нәшриятында китап итеп бастырып чыгарырга тәкъдим иткән булса кирәк. Муса әфәнде бу тәкъдимне, әлбәттә, кабул итә һәм үзе ясаган Коръән тәрҗемәсен китап итеп бастыру хокукларын Җамал Кутайга тапшыра. Бу турыдагы килешү рәсми нотариаль процедуралар аша уза һәм, килешүче ике тарафтан тыш, шаһитлар тарафыннан да имзалана. Түбәндә бу документның татарчага тәрҗемәсе тәкъдим ителә:

«*Төркия җөмһүрияте*[2]

*28097*

*Җамал Кутай*

«*Millet*» *һәм* «*Hakka Doğru*» *сахибы*

*Истанбул*

*Коръән кәримнең төрекчә тәрҗемәсендә әледән-әле латин хәрефләренең кулланылу тәҗрибәсенә иябез. Бу көтелгән хезмәтләребезнең тулы һәм камил мәгънәсе белән мөмкин була алмаячагын күрсәтте.*

*Бу йөздән сүрәләрнең аңлатмаларында һәм бары тик Төрек хәрефләре белән аңлатылуы мөмкин булмаган өлешләрдә гарәпчә текстларның кушылып бирелүен тәэмин итү зарурәте барлыкка килде. Бу максат белән, һәм сәламәтлек ягыннан хәлемнең яхшы булмавы белән бергә, Мисырга сәяхәт кылырга әзерләнәмен. Ярты гасырлык хезмәтемне үз эченә*

[1] Җәмал Кутай (1909–2006) – тарихчы, язучы, публицист, нашир. 20 нче еллар азагында «Hakimiyet-i Milliye» газетасында эшли. Коньядә яшәгән дәверендә «Yeni Anadolu» газетасы белән «Zaman» журналына нигез сала. Истанбулга күчкәч, «Hakka Doğru» белән «Millet» журналларын чыгара. Күп санлы тарихи хезмәтләр язган, шул исәптән: 20 томлык «Türkiye İstiklal ve Hürriyet Mücadeleleri Tarihi», 9 томлык «Tarih Sohbetleri», «Bilinmeyen Tarihimiz» кебек китапларын атап була.

[2] Чыганак: Millet. 18 Kasım 1948. Sayı 145. Sene: 3.

*алган тәрҗемәне булдыклы һәм асыл милләтебезгә тәкъдим итү эшендә хаслап сезне җаваплы итәм һәм аны Төркиядә нәшер итү хакын, башка һичнинди шартлар куймыйча, сезгә саклануга тапшырып бүләк итәмен.*

*Бөтен кыйммәте, мәңгелек эчтәлеге үз телебездә һәм асылына тәмам туры килә торган гыйбарәләрдә тупланган (төрекчә Аллаһ кәламын) көткән һәм укырга теләгән ватандашларымнан бары тик Каһирәдә басылуы мөмкин булган текстлар тәмамланганчыга кадәр сабырлы булуларын үтенәм. Әсәремнең газиз Төркиябездә нәшер итү хакын сезләргә калдыруымны, саклауга тапшырып бүләк итүемне нотариус каршысында раслыйм.*

*Истанбул Йешилдирек Җафер ага урамындагы 13 номерлы Бакыркөй мөфтие Али Риза Хайырлы ханәсендә яшәгән Муса Җаруллаһ Биги*
*(имза).*

*Каршыбызда укылган вә аңлатылган бу бүләк итү игъланы астындагы имзаның без белгән Муса Җаруллаһ Бигинеке булуын раслыйм. Истанбул Йешилдирек Җафер ага урамы 13 номерлы [йортта] яшәүче Бакыркөй мөфтие Али Риза Хайырлы*
*(имза)*

*Истанбул Лалели Шагыйрь Хасмет урамы 48 номерлы [йортта] яшәүче Шереф Шерпынар*
*(имза)*»

Әлеге документ янәшәсендә үк «Millet» журналының мөхәррире буларак Җамал Кутай үз кулы белән язган редакция мәкаләсендә Муса Җаруллаһның журнал укучыларына булган үтенечен җиткерә:

«*«Милләт»нең редакциясе төрекчә Коръән кәрим хакында*[1]

***Остаз Муса Җаруллаһ Биги хәзрәтләре укучыларыбызга бер үтенечен белдерә…***

*Матди-рухи барлыгыбызны бары тик ышанычлы һәм үзебезгә якыннан таныш булган чыганаклардан ала торган «Милләт» һәм «Хакка догру»ның мөхтәрәм укучыларының*

[1] Чыганак: Millet. 18 Kasım 1948. Sayı 145. Sene: 3.

*игътибарына. Газиз милләтебезгә күрсәтә алган хезмәтләребезнең иң кыйммәтлесе буларак, дәверебезнең бөек һәм тиңдәшсез дин галиме остаз Муса Җаруллаһ Биги хәзрәтләре башкарган Коръән кәримнең төрекчә нөсхәсен тәкъдим итүне инде күптәннән теләгән идек.*

*Аллаһ кәламына ул лаек булган тиңдәшсез урынны даимән биреп торган бөек төрек милләте игелеклелеге дөньяга танылган кодрәтле фикер иясенең илле ике еллык хезмәтен гәүдәләндергән әсәргә карата хәйран калдырырлык кызыксыну һәм теләктәшлек күрсәтте. Илебезнең һәр тарафыннан берникадәр ватандашларыбыз үз исемнәрен теркәттеләр һәм өлешчә акчалата һәдияләрен дә юлладылар.*

*16-шар битлек 50 табак хәлендә 800 сәхифәле булачагын үзебез раслаган әсәрнең беренче томын тәшкил иткән ун табак күләмендәге өлешен тәртипкә салганда остаз, гарәпчә текстның бер тарафта биреләчәге турында карар кылып, канәгатьләнгән иде. Чынлыкта, тәрҗемә белән янәшә бәхәсфәлән ителмәячәк кадәр үзгәрешсез булган асыл Коръән тексты биреләчәгенә барыбыз да риза булган бу нәтиҗәне газиз укучыларыбызның бәяләвенә тапшырабыз. Хәзерге вакытта, остазыбыз ярты гасырдыр хәсрәт кичергән ватаныннан аерылган булуына һәм сәламәтлегенең начараюына карамастан, чын иман иясе булган кешеләргә хас була торган фидакярлек хисе белән, исемен мәңгеләштерәчәк әсәрен тулысынча җиренә җиткереп башкару максаты белән Мисырга сәяхәткә әзерләнә. Каһирәнең иң зур матбагаларыннан берсендә басылачак булган гарәпчә текстларның беренче ун табагы тәмамланган вакытта, аларның каршы сәхифәләре матбагабызда төрек хәрефләребез белән басылачак һәм сезләргә тәкъдим ителәчәктер.*

*Коръән кәримнең бу шәкелдәге чыгымнары әле томлап җыелганчы ук ун лирадан күпкә артып китә. Бөек әсәргә лаек рәвештә томлап җыелган хәлдә, безнең тарафтан чыгымнарын сигез лира буларак раслаган әсәрнең бу бәя аермасын, булган мөмкинлекләребез исәбенә, без түләячәкбез*

*һәм бу рухи хезмәтебезне кечкенә бер бүләгебез буларак кабул итүегезне үтенәбез.*

*Остазыбыз безгә чынлап та зур бер ышаныч күрсәтеп, гомерен сыйдырган искиткеч әсәренең Төркиябездә басылу һәм нәшер ителү хакын Җамал Кутайга тапшырды һәм бүләк итте. Без лаек булган бу ышанычны хәятебезнең соңына кадәр дәвам иттерү безнең шәрәф һәм вөҗдан бурычыбыздыр.*

*Көтеп алган әсәрегезнең бу хәлдә тагын да яхшы булачагы шөбһәсездер. Асыл гарәп тексты белән төрекчәгә тәрҗемә арасында чагыштыру гарәпчәне белгәннәр өчен мөмкин булачактыр. Остазыбыз да бу фикердәдер һәм мөхтәрәм дин кардәшләреннән бераз тагын көтүләрен үтенә. Бу вакыт эчендә әсәр өчен акчалата бүләкләр җибәргән хөрмәтле укучыларыбызның, тәрҗемәне сатып алу теләген белдергәннәрнең әманәтләрен үтәргә өметләнеп торабыз.*

*Ислам динен тотучы төрек йортлары дәрәҗәсе мәңгелек булган бу асыл әсәргә ия булу юлындадырлар. Моңа инанабыз».*

Ошбу документлардан аңлашылганча, Муса әфәнде соңгы көненә кадәр Коръән тәрҗемәсен бастыру нияте белән янган һәм бу эшне башкарып чыгар өчен мөмкин булган һәм кирәкле дип санаган һәр эшне эшләгән. Коръән тәрҗемәсен бастыру хокукын Җамал Кутайга тапшырганда ул үзенең гаять кыен матди хәлен дә кайгыртмаган, чөнки бу хокукны акча бәрабәренә алыштырмаган. Аның максаты гомеренең иң олы хезмәтен тәшкил иткән Коръән тәрҗемәсен халыкка ирештерү булган. Тәмам картайган һәм хәлсезләнгән Муса әфәндене тәрҗемәне җиренә җиткерү өчен, Мисырга барып, анда яңа төрек язулы, ягъни латин хәрефләре белән җыелган тәрҗемә янәшәсендә урнаштырыр өчен Коръән текстының гарәпчәсен җыярга кирәк булуы да куркытмаган. Килешүгә кул куелгач та, Муса әфәнде, эшне озакка сузмыйча, Каһирәгә китеп барган. Аның Төркиядән китеп барган көнен янә Гаяз әфәнденең бер хатыннан укып беләбез: «*Муса әфәнде айның 12 сендә вапур берлә Мисырга китте. Аның белән бергә теге*

*гокаля хатын Фатыйма Алчин да китде. Икесенең дә юллары ачык булсын. Муса әфәнде төрле-төрле шәрык дипломасилар ясап маташып, үзенең хөрмәтен шактый югалтып китде. Хәерле булсын*»[1].

Бу хатта сүз 1948 елның декабрь ае турында бара. Шулай итеп, Гаяз Исхакыйның хатлары ярдәмендә, Муса әфәндегенең Төркиягә 1947 елның сентябрь аенда килеп, 1948 елның 12 декабрендә Каһирәгә юл тоткан булуы ачыкланды. Димәк, Истанбулда Муса әфәнде бер елдан артык вакытын үткәрә.

Гаяз Исхакыйның бу хатында Муса әфәндегә карата сизелгән үпкәсенең дә сәбәбен ачыклыйк. Чыннан да, искә алынган вакыт дәвамында Төркиядә яшәгәндә Муса әфәнде, кайбер эшләрен фаш итмичә, үз көенә туры китереп эшләгән. Сүз аның мәшһүр, әмма әлегә кадәр табылмаган Коръән тәрҗемәсе турында бара. Аның бу кадәр олы һәм мөһим хезмәтенә кагылышлы хәрәкәтләренең Исхакыйның игътибарыннан читтә калуы, әлбәттә, сәер хәл. Исхакый, мөгаен, Муса әфәнденең бу эшчәнлеге турында белми калуына аптырап та, рәнҗеп тә алгандыр. Бәлки шуңа күрә ул бу хатында шундый сүзләр язгандыр. Күрәсең, Муса әфәнденең Коръән тәрҗемәсен бастыру тирәсендәге хәрәкәтләре турында Исхакыйга аны-моны сиздермәвенең аерым бер сәбәбе булган. Мәсәлән, 1912 елда Коръән тәрҗемәсен бастыру мәшәкатьләре белән Казан һәм Санкт-Петербург арасында йөреп кайнашкан көннәрендә Гаяз Исхакый Фатих Әмирханга язган бер хатында Муса әфәнде ясаган Коръән тәрҗемәсе турында болай дигән: «*…мин хәзер Мусаның татарча Коръәнен басдыруга каршы киләм… Мусаның хакыйкатән файдалы вә кирәкле эшендә гомум халкымыз файда итәр урында (вакыты җитеп бетмәгәнгә күрә), хәзер зарар гына итәр дип иман китерәм*».

Бу кадәресен генә Муса әфәнде, һичшиксез, күтәрер иде, чөнки Исхакый да бит Коръән тәрҗемәсен бастыруның әле вакыты килмәгәненә басым ясаган булса да, асылда файдалы нәрсә булуын таныган. Әмма алга таба ул хатта мондый

---

[1] Исхаков. Күрс. кит., б.163.

сүзләргә тап булабыз: «*Муса – рухан*[1] *гарәп, сарт, фарсы, әллә кем, иң тугрысы, шулардан ясалган ботка. Мусаның теле тел түгел. Аны госманлы төрекләре – татарча, ди, татарлар – төрекчә, ди, кырымлылар – фарсыча ди икән, дөресте, берсе дә түгел. Шул телләрдән ясалган хәерче капчыгы. Менә шулар өчен мин Мусаның иң зур хезмәтендән булган шул хезмәтендән кирәгенчә файдалана алмыймыз дип куркам*»[2].

Муса әфәнденең язма теленә карата бирелгән мондый тискәре һәм, хәтта, мыскыллы бәя теге яки бу юл белән аның үзенә дә ирешә алгандыр, мөгаен. Һәрхәлдә, Исхакый үзенең бу фикерләрен халыкка җиткерергә омтылган була. Моның өчен ул аларны Фатих Әмирхан чыгарган журналда бастырып чыгаруны тәкъдим итә. Әгәр бу сүзләр Муса Җаруллаһка журнал ашамы, башка юллар беләнме – ирешкән булса, аның күп еллар үтеп китеп, гомеренең азагында Коръән тәрҗемәсен бастыру эшләре белән яңадан кабынып киткән көннәрендә Гаяз Исхакыйга бу хакта хәбәр бирмәве аңлашыла. Шуңа күрә Коръән тәрҗемәсенә караган яңалыкларны да Гаяз әфәнде бары тик Төрек матбугаты сәхифәләреннән белеп ала.

Муса әфәнде 1947–1948 елларда Төркиядә яшәп алган чагында җирле матбугат сәхифәләрендә аның бер бәйләм мәкаләләре басылып чыга. «İslam-Türk Ansiklopedisi Muhitulmaarif Mecmuası» исемле фәнни җыентыкның 1947 ел октябрь санында аның «***Müsülmanlık Hayat Kanunudur, Müsülmanlık Hayat Hukukudur***» («Мөселманлык яшәеш кануныдыр, мөселманлык яшәеш хокукларыдыр») исемле мәкаләсе дөнья күрә. 1948 елда югарыда инде телгә алынган «Selâmet» журналы галимнең язмаларыннан гыйбарәт булган бик күләмле бер цикл башлап җибәрә. Аның 16 мәкаләсе 1948 елда, ә калган өлеше, ягъни тагын 31 мәкалә, 1949 елда дөнья күрә. Бу мәкаләләр арасында Мөхәммәт пәйгамбәрнең биографиясенә, шигыйлыкка, Коръәннең Мөхәммәт пәйгамбәр турында биргән хәбәрләренә багышланганнары бар. Гомумән алганда, Һиндестанда бастырган китаплары белән

[1] рухан – рухы белән; рухи яктан.

[2] Исхаков. Күрс. кит., б. 23.

бергә бу журнал публикацияләре галимнең гомер азагында дөнья күргән иҗат җимешләрен тәшкил итәләр. Китабыбызның кушымтасында Муса әфәнденең «Selâmet» журналында басылган әсәреннән бер өзек китерелә[1].

## Гомеренең Каһирәдә үткәргән соңгы айлары (декабрь 1948–1949, октябрь)

Инде Муса әфәнде гомеренең Каһирәдә үткән соңгы айлары турында гына әйтәсе калды. 1948 елның 12 декабрендә Истанбулдан пароход белән юлга чыккан остаз Мисырның башкаласына, диңгез аркылы узган юлын истә тотсак, 14–15 декабрьдә барып җиткән булса кирәк. Аның биредә ниләр күргәнен югарыда искә алынган Йосыф Уралгирәйнең язмаларыннан һәм яңа гына табылган башка кайбер чыганаклардан белә алабыз. Үзенең хатирәләрендә Йосыф әфәнде Уралгирәй Муса әфәнденең Каһирәгә икенче кат килүе турында болай дип яза: «*Остаз бу юлы Истанбулдан Каһирәгә Русиягә китү фикереннән ваз кичеп килде. Юлдаш буларак янында казанлы Фатыйма ханым да бар иде. Авырып китүе сәбәпле университет буенча дусты вә заманының Вакыфлар министры Гали Габдерразикъ*[2] *бәйнең арадашлыгы белән аны «Калавун хас-*

[1] Карагыз: III Бүлек. 24: «Коръән кәрим» тәрҗемәсе.

[2] Гали Габдерразикъ (1888–1966) – укымышлы мисырлы дин әһеле гаиләсендә туа, 1912-дә «әл-Әзһар» университетын тәмамлый. Көнбатыш гыйлемнәрен Карло Альфонсо Наллино (Carlo Alfonso Nallino), Дэвид Сантиллана (David Santillana), Энно Литман (Enno Littmann) кебек шәркыятчеләрдән үзләштерә. Оксфорд университетында икътисад буенча белем ала башлый, әмма, Җиһан сугышы башлану сәбәпле, 1915-тә кире Мисырга кайта. 1925 елда «Әл-Ислам вә усулү-л-хүкм» исемле китабының дөнья күрүе сәбәпле, кискен тәнкыйть һәм гаепләнүләргә дучар ителә һәм «Әл-Әзһар»нең голәмәләр сафларыннан чыгарыла. Сәяси эшчәнлеккә «Хизбү-л-әхрар әд-дүстүрийййин» исемле партия вәкиле буларак кереп китә. Ибраһим Һади Паша хөкүмәтендә 1948–1949 елларда Мисыр Вакыфлар министрлыгы җитәкчесе булып тора. (Чыганак: https://islamansiklopedisi.org.tr/ali-abdurrazik (26.05.2019 мөрәҗәгать ителде).

*таханәсе»нә урнаштырдым. Мәхрүмгә*[1] *алты Мисыр лирасы кадәр айлык та билгеләнде. Хастаханәдә сидек капчыгына һәм катарактага операцияләр кичерде. Хәле искитәрлек түгел иде. Йөрәк җитешсезлеге башланган иде»*[2].

Муса әфәндене бәхетенә, ул чакта Каһирәдә Габдерәшит казыйның кызы Фәүзия ханым Догрул[3] яшәгән. Фәүзия ханымның тормыш иптәше Нафиз әфәнде Догрул ул елларда Каһирәдә Төркия Баш консуллыгында дипломатик хезмәттә була. Өстәвенә, Нафиз Догрул – Муса әфәнденең дусты, югарыда искә алынган Гомәр Рыза Догрулның бертуган кардәше[4]. Фәүзия ханым Муса әфәндене авыр хәлдә калдырмый һәм, Каһирәдә яшәгән елларында, Мисыр аксөякләре белән корып өлгергән дустанә элемтәләрен файдаланып, мөмкин булган кадәр уңай шартлар тудырырга тырыша. Бу хакта Уралгирәйнең хатирәләрендә язылган: «*Бу арада казый Габдерәшит Ибраһим әфәнденең кызы Фәүзия Нафиз Догрул ханым тарафыннан да* [Муса әфәнденең.– А.Х.] *хәле Хи-*

[1] мәрхүм (Аллаһның рәхмәте белән кавыштырылган (үлгән) – Уралгирәй бу мәкаләсен язганда Муса әфәнде инде күптән үлгән була.

[2] Uralgiray. Önsöz, s. XIX.

[3] Габдерәшит кызы Фәүзия Нафиз Догрул (Ибраһим); 1887–1985) – Габдерәшит Ибраһимнең беренче хатыныннан туган ике кызының берсе. Татар эмиграциясенең күренекле вәкиле, актив җәмәгать эшлеклесе, мәгърифәтче. 1921 елдан башлап Төркиядә яшәгән. Татар һәм урыс телләреннән тыш, гарәп, төрек, француз һәм инглиз телләрен белгән. 1925 елдан башлап Истанбулда «Асар-ы нисван», соңрак «Kadın Yazıları» исеме белән чыккан хатын-кызлар журналын нәшер итә. 1949 елда Каһирәдә Мөхәммәт пәйгамбәрнең тормышы турында француз һәм инглиз телләрендә балалар өчен язган ике китабын бастыра. Тулырак мәгълүмат өчен карагыз: Хайрутдинов А. Г. Общественная деятельность Фаузии Ибрагимовой. Minbar. Islamic Studies. 2022; 15(2):303–324. https://www.minbar.su/jour/article/view/1097/625

[4] Аксой, Неслихан Арул. История моей семьи. Фаузия Габдерашит / Ибрагимова Ф. Мастер кулинарии: подарок для дам = Аш остасы: ханымнарга һәдия.– Казань: Изд-во «Познание» Казанского инновационного университета, 2017. С. 26.

*див Тәүфыйкның кызы гыйлем вә игелек яратучы принсес Хәдиҗәгә*[1] *җиткерелде. Күптәннән инде шагыйрь Мехмет Акиф*[2] *бәйне химаясенә алган бу принцес бу юлы Муса әфәндене дә химаясенә алды. Мәрхүмә энисе Вәлидә-и Паша Өмме-л-Мөхсининнең*[3] *Мисыр әл-кадимәдә*[4] *төзеткән ялгызлар хозур йортында*[5] *докторлы, комфортлы, хезмәткәрле яхшы һәм иркен бер бүлмә булдырды. Бик кайгыртты»*[6].

---

[1] Хәдичә (Фәхренниса Хәдичә ханым; Princess Hadice Abbas Halim; Каһирә, 2 май, 1879 – Каһирә, 22 февраль, 1951) – Мисырның 2 нче хидиве буларак 1879–1892 елларда идарә иткән Тәүфыйк Пашаның (1852–1892) кызы.

[2] Акиф Эрсой (Мөхәммәт Акиф Әрсой; 1873–1936) – Төркия дәүләт гимнының (İstiklal Marşı, Milli Marş) сүзләрен язган шагыйрь. Төркия парламенты депутаты була, тәрҗемә, укытучылык белән шөгыльләнә. 1923 елда Мисыр соңгы хидиве (хөкемдары) Габбас II Хильми Пашаның (1874–1944) чакыруы белән Төркиядән Мисырга күчеп китә һәм 1936 елга кадәр Каһирәдәге «Мисыр университеты»нда төрек теле укыта. 1936 елның август аенда кире Төркиягә кайтып китә һәм декабрь аенда туган илендә вафат була. Рыза Догрулның каенатасы.

[3] Вәлидә-и хидив / Вәлидә-и паша (Хидивнең/Пашаның әнисе) – сүз Мисырның соңгы хидиве (хөкемдары) Габбас II Хильми-пашаның әнисе Әминә ханымсолтан (Әминә Ибраһим Илһами, 1858–1931) турында бара. Әминә-ханымсолтан үзенең матди байлыгының зур өлешен сәдәка вә хәйрия максатларында сарыф иткәнгә күрә, халыкта ام المحسنين Өмме-л-мөхсинин (Игелек кыйлучыларның анасы) исемен, ә гыйлем, галимнәрне һәм гыйлем алуны кадерләгәне өчен Сәййидәт әт-тәгълим (Гыйлем бирүнең сәййдәсе) исемнәрен казана.

[4] Мисыр әл-кадимә (Иске Мисыр) – Каһирә шәһәренең борынгы өлеше. Мисыр дип Каһирәне дә атый торган булганнар.

[5] Әмир оглу әфәнденең хатирәләрендә әлеге гаҗизләр йортының гарәпчә яңгырашы «Мәлҗәә-л-гаҗәзә» буларак бирелә, ягъни «Гаҗизләр ханәсе». Әмма бу йортның тулы рәсми исеме «Мәлҗәә Өмме-л-мөхсинин» була, ягъни ««Өммел-Мөхсинин» үксезләр ханәсе». Өмме-л-Мөхсинин дигәндә принсес Хәдичә Хәлимнең әнисе Әминә Илһами ханым күздә тотыла.

[6] Uralgiray. Önsöz, s. XIX–XX.

Шулай итеп Уралгирәй ярдәме белән «*Калавун хастаханәсе*»нә салынып, анда операцияләр кичергәннән соң, 1949 елның июнь аенда Муса әфәнде «*Мәлҗәэ Өмме-л-Мөхсинин*» дип аталган кемсезләр ханәсенә күчерелә. Бу вакыйгалар турында Баттал-Таймасның язмаларыннан тагын да төгәлрәк мәгълүмат табылды[1]. Бу чыганакта Фәүзия ханым Догрул үзе хәбәр иткән мәгълүматлар булганга күрә, үтә дә кызыклы һәм әһәмиятле. «*Musa Carullah'ın Kahire'de geçirdiği son günleri*» («Муса Җаруллаһның Каһирәдә үткәргән соңгы көннәре») исемле бер бүлекчәдә Баттал-Таймас болай дип язган: «*Муса әфәнденең 1948 елның соңгы көзендә (12 декабрьдә) Истанбулдан аерылып Каһирәгә барганыннан соң анда кичергән соңгы көннәре турында мәгълүмат кытлыгы аркасында 2 номерлы әсәребездә һичбер нәрсә язмаган идек. Әсәр басылып таралганнан соң күрештегем хөрмәтле Фәүзия Габдеррәшит Догрул ханымның миңа игелек кыйлып язулы буларак биргән мәгълүматлардан түбәндәге өстәмәне чыгардым.*

*Муса әфәнде Каһирәгә баргач Румыния төрекләреннән (асылда Кырымлы димәк) һәм Җамиг-ы Әзһәрне тәмамлаган Йосыф Вәлишаһ атлы бер затның өендә торган. Фәүзия Габдеррәшит ханым һәм ире Нафиз Догруллар аны үз өйләренә алырга теләсәләр дә, остаз шәһәр эчендә калырга теләвенә өстенлек биреп, бу тәкъдимне кабул итмәгән. (Догрул гаиләсе ул вакытта Каһирәдән поезд белән 45 минутлык җирдә,*

---

[1] Китереләчәк мәгълүмат чыганагы күрсәтелмәгән, төрек телендә язылып ксерокста ясалган бер нөсхәдән алынды. Нөсхәне ясаучы басма турындагы мәгълүматны да кушуны кирәксенмәгән. Әмма анда язылганнардан аңлашылганча, бу нөсхә Баттал-Таймас тарафыннан язылган ниндидер китаптан алынган. Аның Муса әфәндегә караган өлеше «II Üstad Musa Carullah Üzerine Notlar» («II Остаз Муса Җаруллаһ турында язмалар») дип атала. Берникадәр эзләнүләрдән соң, бу текстның Баттал-Таймас язган ике китапта өстәмә рәвешендә басылган булуы фараз кыйлынды: йә 1958 елда Истанбулда чыккан «Âlimcan Barudî» («Галимҗан Баруди») исемле китап, йә булмаса шунда ук 1959 елда чыккан «İki Maksudîler: Sadri Arsal-Ahmed Hâdi» («Ике Максудилар: Садри Арсал-Әхмәт Һади»).

*Король Фарукның апасы Принсес Нимәт Мохтарның утарында яшәгәннәр).*

*Хастаханәдә – Муса әфәнде инде Истанбулдан ук авыру хәлдә юлга чыккан булган. Каһирәдә хасталыгы көчәйгәннән Йосыф Вәлишаһ ул көннәрдә Вакыфлар назиры (вәкиле) булып эшләгән галим Гали Габдерразикъка баш орган һәм Вакыфлар хастаханәсенә яткызу өчен ярдәмен алган.*

*Назир, Муса әфәндене абруе һәм гыйлемен кадерләүчеләрдән буларак, аңа алты Мисыр лирасы кадәр мәгаш та билгеләгән һәм хаста яхшы дагылсын өчен әледән-әле күрсәтмәләр җибәреп торган.*

*Әмма назирның бу кайгыртуларына карамастан, хастаны багу һич тә яхшы булмаган: аңа хәтта кирәге кадәр азык бирелмәгәнгә күрә, хаста гадәттә ач булган, авыруы тагын да көчәйгән. Хәлбуки остазның дәваланудан күбрәк ашауга ихтыяҗы булган. Ләхистан мөселманнарының элекке мөфтисе һәм Каһирәдә эмигрант буларак көн күргән Йагъкуб Шенкевич, җәмгыятьче «голяма»дан казанлы Галимҗан Идриси һәм бер доктор булган ише моның турында белгәннәр дә Фәүзия ханым Догрулга мөрәҗәгать итеп, остазны бу ачлыклы хәлдән коткару өчен бер чара табуын үтенгәннәр».*

Алга таба Баттал-Таймас безнең өчен үтә дә кызыклы булган документ китерә. Сүз Фәүзия ханымның аңа язып җибәргән хатирәләренең бер өлеше турында бара. Фәүзия ханым болай дип язган:

«*Үксезләр йортында.*

*Хидив Габбас Халимнең әнисе (Вәлидә-и Паша) ның төрек картларына махсус буларак ачкан «Дарул-гаҗәзә» бар иде. Аны кызы принсес Хәдичә идарә итә иде. Акылыма шул килде дә Идрисинең иптәшенә: «Иртәгә Муса әфәндене шунда күчертикме?» дидем. Бу фикеремне алар да мөнасип күрделәр. Иртәгесе көн иртән принсес Хәдичәнең Хильвандагы сараена киттем һәм мәсьәләне аңлаттым. Принсес бик тәэсирләнде һәм: «минем хисабыма кыйммәтле бер әҗнәби*[1] *хастаханәгә*

[1] әҗнәби – чит; чит илгә караган; чит илнеке.

*яткызыйк», диде дә телефоннан үзенең кятибен*[1] *чакырды һәм мәсьәләне аңлатты. Кятиб исә, минем фикеремне яхшырак күрде һәм «Мәлҗәъ»тә үзенә бер бүлмә бирелеп хастаның үзен тагын да яхшырак тоячагын аңлатты. Шунда ук тиешле әзерлек күрделәр һәм хастаны «Мәлҗәъ»кә күчерделәр. Тик үзен генә багу өчен бер ир хезмәтче тәгайен ителде. Принсесның шәхси докторының күзәтүе астында яшәячәк булды.*

*Арадан берничә көн үткәч азәрбайҗанлы дусларыбыздан Али Хәйдәр әфәнде, ирем Нафиз бәй һәм мин Муса әфәндене зиярәт иттек; тубал кебек шешенгән иде; куркыныч бер хәлдә иде: хәтта күзләре дә күрми иде; безне бары тик тавышларыбыздан таныган иде. Хәлнең мондый булуы белән бергә, хаста биредә үзенә бик рәхәт булуы; багылуы һәм ихтирам күрүе: азык-төлек, чәй һәм башка ни теләсә – шуны күп итеп бирүләре һәм үзен биредә яхшырак хис итә башлавы турында сөйләде. Яткан бүлмәсе бик зур иде; чиста бер бакчага караган тәрәзәләре бар иде, мебельләре гади иде. Шкафында мөкәммәл чәй җиһазлары һәм спиртта эшли торган учагы тора иде. Үзен кыйммәтле һәм люкс юрганнар белән кат-кат ураганнар иде.*

*Остаз үзенең бик рәхәт булуын әйтеп торса да, без аның янынннан өметсез бер хәлдә аерылдык.*

*Әмма аның Вакыфлар хастаханәсендәге хәлен күргәннәр бик оптимист иделәр: хастаның бүген бик яхшы хәлдә булуын әйтәләр иде һәм «яңадан хәяткә кавышты» дияләр иде».*

Искә алынган язмада Фәүзия ханым Муса әфәнде яздырган васыять турында да мәгълүмат китергән:

«*Васыятьнамә.*

*Беркадәр вакыттан соң Йосыф Вәлишаһ безгә телефоннан шалтыратты да: «Муса әфәнде васыятен яздырачак, бу арада сез әзер булыгыз», диде. Ирем бармады, мин үзем генә бардым һәм юлда Галимҗан Идриси эшләгән Гарәп берлегенә кереп, аны да ияртеп алып бардым. (Идрисинең Йосыф Вәлишаһ белән аралары бозылган иде).*

[1] кятиб – секретарь.

*Бу юлы Муса әфәнде күренешенең яхшырак дип таптым. Тәнендәге шешләр кими төшкән. Ятагында сузылып яткан, һәркем белән сөйләшә ала иде. Һәм бу арада: «Принсес мине белми; аның тарафыннан кылынган бу хөрмәтләргә сез сәбәпче булдыгыз», дип, ирем Нафизгә һәм миңа догалар кыла иде.*

*Васыятьнамәсен кечкенә бер кәгазьгә Йосыф Вәлишаһка әйтеп торып яздырды: үзеннән соң калачак булган әйберләрне, акчаларын, Һиндестанда бер ханымның янында калдырган берничә рус алтынын ул заман Русия тышында яшәгән углы Әхмәткә тапшырылуын; китапларының Әнкарадагы Милли китапханәгә тапшырылуын яздырган иде. Анда булган безләр һәммәбез шаһит сыйфатында имзаларыбызны куйдык.*

*Үзе белән Истанбулдан килгән Фатыйма ханым да анда иде. Шул чакта Йосыф Вәлишаһ Муса әфәнденең Вакыфлардан алган 6 лира мәгашын китергән иде. Муса әфәнде алды һәм Фатыйма ханымга бирде*».

Алга таба Фәүзия ханым, 1949 елның җәен Истанбулда үткәрер өчен Каһирәдән китеп торырга җыенган арада, Муса әфәнде белән хушлашыр өчен аны тагын бер кат зиярәт итә: «*1949 елның июнь ае иде. Җәйне үткәрер өчен Истанбулга китәчәк идем дә, Муса әфәнде белән хушлашу өчен «Мәлҗәъ»кә кереп чыккан идем. Остаз мине аякта каршылады. Хәятеннән, сыйххәтеннән бик разый иде. Хиҗазга барырга, соңгы көннәрен шунда үткәрергә һәм шунда үләргә теләве турында сөйләде. Мин: «Озын диңгез юлын күтәрә алмаячаксыз. Биредә тагын бераз ял иткәннән соң принсес Хәдичәдән үтенербез: сезне шунда очкыч белән илтеп куярлар» – дидем. Бер бала сыман сөенде. Мине капкага кадәр озатты. Картлыктан башка шикаяте юк иде*».

Истанбулга кайткач, Фәүзия ханым Муса әфәнденең Каһирәдәге хәлләре турында Төркия матбугатында бер хәбәр бастырган. Сүз «Selâmet» журналының 1949 ел июнь ае ахырында чыккан санында «*Муса Җаруллаһ. Премьер-министрга бер үтенеч*» исемле мәкалә[1] турында бара. Аның тәрҗемә-

[1] Musa Cârullah. Başbakandan Bir Rica. Selâmet, 29 Haziran 1949. Cilt IV. Sayı 25–93. S. 3,13. (кыскартылып бирелә).

сен түбәндә китерәбез: «*Хөрмәтле остаз Муса Җаруллаһ хакында мәрхүм бөек ислам сәяхәтчесе һәм ислам миссионеры Габдерәшит Ибраһимның кадерле кызы Фәүзия ханымнан бик яхшы мәгълүмат алган булуыбызны укучыларыбызга кичектермәстән белдерергә телибез. Бөек остазыбыз Габдерәшит Ибраһимның кызы Фәүзия ханым бу җәйне Истанбулда үткәрер өчен килгән һәм безгә остаз Муса Җаруллаһның хәле хакында гаять яхшы мәгълүмат бирде. Остаз хәзерге хәлдә Каһирә «Мәлҗәэ Өмме-л-Мөхсинин»*[1] *исемле хастаханәдәдер. Мәрхүмә Вәлидәи хидив тарафыннан төзетелгән бу хастаханәдә дәваланган остаз Муса Җаруллаһ хастаханәгә нигез салучы Вәлидәи хидив хәзрәтләренең кызы принсес Хәдичә ханымәфәнде хәзрәтләре тарафыннан химая ителгән һәм дәвалануы өчен кулдан килгән һәр гайрәтнең сарыф ителүе тәэмин ителгән. Принсес ханымәфәнде хөрмәтле остазның иң зур игътибар күрүен кайгырткан һәм шуның аркасында остаз, Аллаһка күп шөкер, бик яхшырган. Әле үзе бу хастаханәдә калуын дәвам итә һәм үзе бик яхшы багылудадыр. Без бу йөздән Фәхре-л-мөхаддәрат*[2] *Хәдичә ханымәфәндегә самими шөкерләребезне белдерүне бер вазифабызга санныйбыз.*

*Икенче яктан хәбәр алганыбызга күрә, Мисыр вакыфлар назире Гали Габдерразикъ Бәй дә мөхтәрәм остазның Вәлидәи хидив хастаханәсендә дәвалануы турында хәбәр алган һәм үзенә бер мәгаш билгеләп, һәртөрле ихтыяҗларын үтәргә теләген белдергән. Муса Җаруллаһның Мисырда күргән бу игътина һәм игътибар ислам кардәшлегенең күп шөкер бөтен җанлылыгы белән яшәвен күрсәтә.*

*Мисыр вакыфлар назире Гали Габдерразикъ Бәйгә дә самими шөкерләребезне белдерүне бер вазифа дип санныйбыз.*

[1] Мәлҗәъ Өмме-л-мөхсинин – «Өмме-л-мөхсинин» (ялгызлар) йорты.

[2] Фәхрел-мөхаддәрат (Хәрәм горурлыгы; Хәрәм даны) – хөкемдар сараеның хатын-кызлар яши торган өлешенең, ягъни хәрәмнең, горурлыгы.

*Кызык, Муса Җаруллаһ кебек бер төрек мөтәфәккиренә бу картлык дәверендә багу һәм бөтен ихтыяҗларын үтәү күбрәк безгә төшмиме?*

*Безнең премьер-министр Шәмсетдин Гүналтайдан үтенечебез – Муса Җаруллаһның хәзер үк мәмләкәткә кайтып, бер хастаханәбезгә дәваланылуын әмер итүедер.*

*Хөрмәтле Шәмсетдин Гүналтай, бер исламият галиме булганы өчен мохакъкак ки Муса Җаруллаһның бик яхшы тәкъдир итәр һәм аның киң фикерлелеген, аның тирән аңлавын, аның нәтиҗәле иҗтиһадлылыгын ихтирам белән каршылар.*

*Без хөрмәтле остазыбыз Шәмсетдин Гүналтайның Муса Җаруллаһны горбәттән коткарып, Истанбулда дәваланылуын тәэмин итүне һәм шул ук вакытта Диңгез юллары гомум мөдирлегенә остазны Мисырдан алып китерүне әмер итүен көтәбез*».

***

Югарыда китерелгән хатирәләрдән аңлашылганча, Муса әфәнденең сәламәтлеге нык какшаган була. Бу сәбәпле Каһирәдә аның Коръән тәрҗемәсен басмага әзерләнү белән шөгыльләнергә һич тә мөмкинлеге булмаган дигән нәтиҗәгә килә алабыз. Чыннан да, беренчедән, аның Каһирәгә килеп төшкән көненнән вафатына кадәр, ягъни декабрь урталарыннан октябрьнең 25-енә кадәр нибары ун ай үтә. Икенчедән, сүз шактый картайган кеше турында бара. Өченчедән, карт кешенең җитди операцияләрдән соң аякка басуы өчен ул ун айның ничәсе киткәнен чамаласак, чыннан да, Коръән тәрҗемәсенә багышларлык вакытның һич калмаганлыгы аңлашылачак. Бу хәлдә Муса әфәнде ясаган Коръән тәрҗемәсенең язмышы нинди булган?

Йосыф Уралгирәй бу хакта мондый мәгълүмат калдырган: «*Хөрмәтле Әхмәт Вәли Мәңгәр бәйәфәндегә күрә бу тәрҗемә Берлин мәчетенең подвалында сакланырга калдырылган китап сандыкларының берсендәдер. Бомбәйдән Каһирәгә китергән китаплары белән бергә, васыятьнамәгә өстәп, Төрек*

*Җөмһүрияте Каһирә Башконсуллыгының хезмәткәре дустым мәрхүм Гомәр Лотфи Мәймән бәйнең күзәтүе астында минем өемдә исемлеге төзелеп, Әнкарага Милли китапханәгә җибәрелде. Рәсми исемлеге минем китапханәмдә саклана. Бу китаплар арасында ул юк. Кайбер әсәрләренең Һиндестанда калган булуы турында әйткәне бар иде. Минемчә, бередә һичбер җирдән табылмавы очрагында һәм 1933 елда Каһирәдә бастырган әсәрендә моның тагын бер мәртәбә искә алынган булу бары тик бу ихтималны калдыра. Ул да әгәр Төркия Бөек Милләт Мәҗлесе тәкъдимен кабул иткән булса иде[1], ул чакта: «Әсәрем Ленинградта, фәләннең кулында калды. Әнкара Хөкүмәтеннән моны илчелек арадашлыгы белән китертүне оештырып табылуын телим»,– дигән булыр иде дип уйлыйм»*[2].

Димәк, Йосыф Уралгирәй Коръән тәрҗемәсен Муса Җаруллаһның китаплары арасында күрмәгән булган. Муса әфәнде дә аңа ул кулъязманың кайда булуын тәгаен генә белдермәгән. Эзләнә торгач, бу мәсьәләнең бары тик Йосыф Уралгирәй язмаларында чагылмыйча, башка чыганакларда да кузгатылган булуы ачыкланды. Мәсәлән, Муса әфәндедәнең вафатыннан соң, Төркия дә чыгып килгән «*Sebilürreşad*» исемле журналның 1949 елның ноябрь аенда чыккан 65 нче санында Шир-Әмир Оглу атлы бер кешенең имзасы белән некролог рәвешендә язылган мәкаләсенә тап булдым. Бу мәкаләдә олуг галимгә карата ифрат зур хөрмәт белдергән автор Муса әфәнде белән танышуы һәм аралашуы турындагы хатирәләр белән уртаклаша, аны югалтудан олы кайгыга төшүен яшерми. Мәкаләнең соңгы өлешендә Шир әфәнде Муса Җаруллаһ башкарып чыккан Коръән тәрҗемәсенең язмышына кагылышлы үтә дә әһәмиятле мәгълүмат китерә: «*Еллар дәвамында эшләп җиренә җиткергән Коръән тәрҗемәсе исә, үзенең миңа кат-кат әйтүенә күрә, алты сандык белән консуллыкка тапшырылган китаплары арасында булырга тиеш булса да, хөрмәтле консул әфәнденең янә миңа әйтүенә күрә,*

[1] 20 нче еллар башында Муса әфәнде үзенең Коръән тәрҗемәсен Төркия парламентына бүләк буларак тәкъдим иткән булган.

[2] Uralgiray. Önsöz, s. XXII.

*ул китаплары арасында булмавыннан, консуллыкка тапшырылыр алдыннан ниндидер бер шәкелдә юкка чыккан, имеш*»[1].

Баттал-Таймас та Коръән тәрҗемәсенең язмышы белән кызыксынган. Аның хатирәләрендә бу турыда мондый сүзләр бар: «*М. Җаруллаһның 1947 елның җәендә үзе белән бергә Истанбулга алып барган һәм 1948 елның җәендә янә үзе белән кире Мисырга алып киткән китап тулы сандыклар бар. Бу хосуста проф. Зәки Вәлиди Тоган миңа: «Без ул сандыкларның эчендәгеләрне дикъкать белән карап чыктык, фәкать анда һичбер Коръән тәрҗемәсенә охшаган бер нәрсә күрмәдек» дигән иде*»[2].

Китерелгән чыганакларга караганда, Муса әфәнде үзенең архивын, китапларын һәм кулъязмаларын Каһирәдәге Төрек җөмһүрияте Башконсуллыгына тапшырып калдырган булган. Элек мин шәхси архивны һәм үзе белән йөрткән китапларны Төркиянең Мисырдагы дипломатик хезмәтенә тапшырып калдыруны Муса әфәндегә нәкъ менә Фәүзия ханым белән аның ире Нафиз бәй тәкъдим иткәннәр булса кирәктер дип уйлый идем. Әмма кулыма кергән һәм бу китапта алга таба китереләчәк чыганакларны өйрәнә торгач, бу фикерем үзгәрде. Һәрхәлдә, Муса әфәнде үзенең архивын һәм китапларын Төркия дәүләт учреждениесенә – Каһирәдәге Башконсуллыкка әманәт итеп калдырган булып чыга. Кайбер мәгълүматлар буенча, архив һәм китаплар Төркия милли китапханәсенә тапшырылырга тиеш була – бу хакта Муса әфәнденең махсус васыять язып калдырган булуы да мәгълүм. Төркиядә чыгып килгән «Ulus» газетасының 1949 елның 22 ноябрь санында «Милли китапханәгә ителгән ике багыш» исемле кыска гына хәбәр китерелә: «*Милли китапханәгә ителгән китап багышлары дәвам итә. Соңгы атналар эчендә Мисырда вафат иткән, ислами гыйлемнәргә кагылышлы әсәрләре белән та-*

---

[1] Emir oğlu, Şir. Allâme Musa Carullah vefat etti. Sebilürreşad. 1949. Cilt: III. Sayı: 65. S. 236.

[2] Battal-Taymas, A. Alimcan Barudî. Kişiliği, fikir hayatı, içtimai-kültürel emekleri ve iki ek. Kazanlı Türk Meşhurlarından III. İstanbul: M. Sıralar Matbaası, 1958. S. 69.

*нылган бөек төрек галиме Муса Җаруллаһ әфәнде 500 том кадәр тәшкил иткән китапларын Төрек милли китапханәсенә вакыф иткән һәм бу китаплар биш сандык эчендә кичә Милли китапханә мөдирлеге тарафыннан кабул ителде. Бу әсәрләр арасында бик сирәк очрый торган һәм кыйммәтле язмалар белән ислами гыйлемнәргә караган мөһим китаплар бар. Милли китапханәнең шәрәф киштәсенә Муса Җаруллаһ әфәнденең бер фотографиясе һәм тәрҗемәи хәле куелачак*».

Димәк, Каһирәдән Әнкарага Муса әфәнденең китаплары һәм архивы шактый тиз арада барып ирешкән. Әмма бу хәзинә Төркиянең Каһирәдәге Башконсуллыгыннан Әнкарадагы Милли китапханәгә барып урнаштырылганга кадәр күпмедер вакыт Төркия Бөек Милләт Мәҗлесендә сакланган. Бу җәһәттән, җай чыккан бер мәлдә Төркия тышкы эшләр министрлыгында эшләүче бер әфәндегә мөрәҗәгать иттек. Аның әйтүенә караганда, Муса Җаруллаһның архивы, чыннан да, Тышкы эшләр министрлыгы аша узып, Әнкарага килеп җиткәч, Бөек Милләт Мәҗлесе архивына тапшырылган булган. Ул елларда анда документларны теркәү-саклау кебек эшләр тиешле дәрәҗәдә булмаганлыктан, шунда эшләүчеләрнең берсе Коръән тәрҗемәсен, имештер, алып чыккан да, шуның белән бу кыйммәтле хезмәтнең эзләре югалган. Шул көннәрдән бирле Муса әфәнде ясаган Коръән тәрҗемәсенең язмышы әлегә кадәр билгеле түгел. Кайчан да булса бу хезмәте дә табылыр дип өметләнеп, Аллаһтан ярдәм сорап догалар кыласы гына кала.

«Мәлҗәэ Өммел-Мөхсинин» хастаханәсендә дәвалана torгач, Муса әфәнденең хәле берара күзгә күренеп яхшырып китә. Бу турыда да хәбәр сакланган. 1949 елның июль ахырында, рамазан гаетенә туры килгән көннәрдә Мисырга «Yeni Selâmet» журналының мөхәррире Гомәр Рыза Догрул әфәнде барып чыга. Максаты Муса әфәндене зиярәт итмәк була. Хастаханәгә Рыза Догрул Муса әфәнденең шәкерте Галимҗан Идриси белән бергә барып, остаз белән күрешәләр. Бу очрашу турында Рыза Догрул «Муса Җаруллаһ белән Мисырда бер очрашу» исемле мәкалә язып чыга. Аны биредә татар теленә тәрҗемә итеп китерергә булдык: «*Докторлар хөрмәтле ос-*

*тазның хәятеннән берара өметләрен өзгәннәр, фәкать ул иманның ялкыны белән тыйб хөкемен тәкзиб иткән, яңадан хәят тапкан.*

*Шикәр бәйрәме*[1] *атнасын Мисырда үткәрү хөрмәтле остаз Муса Җаруллаһны хәзерге хәлдә үзен багу шәрәфенә казандырган хастаханәдә зиярәт өчен иң мөкәммәл чара иде. Без дә Халәбтән*[2] *күтәрелгән Мисыр очкычы белән Каһирәгә барып җитәр-җитмәс хөрмәтле остазның кайда ятканын ачыклаганнан соң, янә Мисырда яшәгән бөек төрек галиме Галимҗан Идриси хәзрәтләренең юлдашлыгыннан файдаланып үзен зиярәт итәргә йөгердек.*

*Бөек төрек мөтәфәккире*[3] *Муса Җаруллаһ «Өммел-мөхсинин» ягъни «Игелек сөючеләрнең анасы» исемен лаеклы сурәттә казанган һәм кылган игелекләре белән Мисырны ихъйа иткән*[4] *мәрхүм Вәлидәи хидив Әминә Тәүфыйк хәзрәтләре төзеткән бер хастаханәдә икамәт итә иде*[5]. *Каһирәдән беркадәр еракта*[6] *булган хастаханә чынлыкта иркен һәм соң дәрәҗәдә мөлаем бер җирдәдер.*

*Хастаханәгә бару өчен Гамру бин Гас җәддәсеннән*[7] *узарга кирәк иде. Бу исемне йөрткән бөек ислам фатихы*[8] *исә Мисырны исламлаштыру кебек мәңгелек бер бәхет казанган бөек мөселмандыр һәм пәйгамбәр әфәндебезнең әсхабеннәндер. Проспектның бер башы ул төзеткән мәчетнең дивары иде. Фәкать бу җәддәдән үткәндә генә дә кешегә өч гасыр элек булган көннәрне хәтерләтеп көч биргән бер нәрсә, бер һава, бер сулыш, бер тизлек сизелә иде. Җәддәнең азагына барып җитмичә трамвайдан төштек һәм күз явын алырдай биналар белән тулы бер җәддәгә чыктык. «Игелексөярләрнең анасы» биредә бер үксезләр мәктәбе һәм бер хастаханә тө-*

[1] Шикәр бәйрәме – рамазан гаете.

[2] Халәб – Сүриядәге шәһәр.

[3] мөтәфәккир – фикер иясе; тирән фикер йөртүче фәлсәфәче.

[4] ихъйа иткән – терелткән.

[5] икамәт итә иде – тора/яши иде.

[6] Каһирә үзәгеннән читтәрәк.

[7] җәддә – проспект.

[8] фатих – яулап алучы.

*зегән һәм без хастаханәнең эченә кереп хөрмәтле остазның икамәт иткән бүлмәгә таба ашыктык.*

*Кыйммәтле юл аркадашыбыз һәм хөрмәтле галимебез Галимҗан Идриси, бөек мөтәфәккиребезне зәррә кадәр исе китмичә атна саен зиярәт итеп торганы аркасында, хастаханәнең юлларын һәм бүлекләрен бик яхшы белә иде. Без дә аның артыннан атладык. Ниһаять, бер бүлмәнең ишеге каршысында туктадык һәм ишек ачык булганга күрә Муса Җаруллаһның сөемле һәм нурлы йөзен күрдек. Йөзе сыйххәт җанлылыгы белән балкый иде. Бу безнең Мисырны бу юлы, ягъни ут кебек янган эссе чагында зиярәт итүебез аркасында кичергән бөтен кыенлыкларны онытгырган иң хәерле бүләк иде. Эчемә тулган сөенеч биргән тизлек белән эчкә атлап, безне каршыларга йөгергән һәм соң дәрәҗәдә сөенгән газиз һәм кыйммәтле остазны кочаклап алдык.*

*Остаз Муса Җаруллаһ, чынлап та, яхшы хәлдә иде. Сыйххәте урынында иде. Шат иде һәм тәмләп-тәмләп сөйләшә иде.*

*Хәлбуки берничә ай элек Истанбулдан Мисырга киткән вакытта хәле чыннан да куркыныч иде. Аякта тора алмаслык дәрәҗәдә зәгыйфьләнгән иде. Күзләре, гадәттә, пәрдәләнгән кебек иде. Укый алмый, яза алмый һәм вакытын үзе теләгәнчә үткәрә алмавы аркасында тирән газап кичерүе йөзенә чыккан иде. Багу, кайгырту, игътибар аның авыруыннан чара була алмый иде, ул да сыйххәтенең начарлыгына карамастан, һава алыштыру һәм хәрәкәт итү ихтыяҗын тоя иде. Үзен сөйгәннәрнең һәммәсен өметсезлеккә төшергән бу хәл Мисырда да дәвам иткән, үзе дә, мөгаен, бер ара өметен өзгән һәм васыятьнамәсен яздыру ихтыяҗын сизгән, китапларын милли китаплыгыбызга багышлаган һәм соңгы сулышын алуын көткән...*

*Докторларның барысы да өметләрен өзгән булган имеш. Һәммәсе дә аның җан бирүенә бик аз калуын әйтә торган булганнар имеш... Һәм бер аралык һәркем Муса Җаруллаһның рәхмәте Хакъка*[1] *күчеп китүен көткән...*

[1] рәхмәте Хакъ – Аллаһның мәрхәмәте.

*Фәкать Муса Җаруллаһ хасталыкка каршылык күрсәткән һәм яңадан терелеп китеп, котылу бәхетенә ирешкән...*

*Бу йөздән һәркем «тыйбның хөкемен тәкзиб итте», ди.*

*Чөнки Муса Җаруллаһ Аллаһның ярдәме белән һәм күңелендә сүнмәгән ялкыны белән бөтен боһраннарга*[1] *каршы торган һәм ахырда хасталыгын җиңеп, сыйххәт һәм сәламәтлеккә кавышкан.*

*Без дә, күп шөкер, аны сыйххәт һәм сәламәтлелектә күреп бәхтияр булдык.*

*Йөзен каплаган нурани бер көлемсерәү олы бер җиңүнең чагылышы иде. Тавышы көр һәм шатлыклы яңгырый һәм кабат эшләү теләге, яңадан язу һәм өммәтнең гыйрфанына*[2] *яңа әсәрләр тәкъдим итү теләге турында сөйли иде.*

*Каршысында торып аның бу хәлен күрү күңелебезне сөенеч белән тулдырган иде.*

*Остазның бүлмәсе гаять төзек һәм матур иде. Биредә үз башына икамәт итә һәм үзенә аерым бер хезмәтче дә беркетелгән иде. Ашаган ризыкларының хосусый бер сурәттә әзерләнүен һәм үзенә тәкъдим ителүен, хастаханә докторларының үзенә ап-аерым бер кайгыртучанлык һәм игътибар күрсәтүләрен ачыкладык.*

*Кызык, аның бу кадәр дәрәҗәдә ихтирам һәм сөю күрүенең сәбәбе ни иде? Моны аңлауда да соңга калмадык.*

*Мәгәр, бу хастаханәгә нигез салучы «Игелексөярләрнең анасы» булган мәрхүм һәм мәгъфур*[3] *Принсес Әминә ханымәфәнденең кәримәсе*[4] *Принсес Хадиҗә Габбас Хәлим хәзрәтләре, мөхтәрәм остазның дәвалану һәм багылуга мохтаҗ булганыннан хәбәрдар булган, шундук үзенә бу ояда урын бирелүен хәл иткән. Муса Җаруллаһны биредә һәртөрле дикъкать һәм ярдәм эчендә дәваларга кушкан...*

*Принсес Хәдиҗә Габбас Хәлим – бөек шагыйремез Мәхмәт Акифнең «Фәхрел-мохаддәрат» исеме белән мактаган*

[1] боһран – хәлнең начараюы, кризис.

[2] гыйрфан – белем, гыйлем; гыйлемлелек, белемлелек.

[3] мәгъфур – гафу ителгән; гафу ителүне казанган.

[4] кәримәсе – кызы.

*шәфкатьлелек гәүдәләнеше һәм хакыйкый кешелеклелек үрнәге булган нәҗиб[1] һәм асыл бер заттыр. Мәрхүм зәвеҗләре[2] Принс Габбас Хәлим паша хәзрәтләре ничәмә-ничә кыйммәтле шәхесләремезне химая иткән һәм бу шәхесләр үзләренең иң тирән әсәрләрен мөмкин кадәр нык тынычлыкта һәм түгәрәк тормыш эчендә иҗат итүләре өчен ярдәмнең һәммәсен кылган иде. Гыйлем, гыйрфан һәм сәнгать белән кызыксыну, һәр кыйммәтле нәрсәгә терәк булу аның эше һәм шигаре иде. Мөхтәрәм һәм мактаулы тормыш иптәшләре Принсес хәзрәтләре бу юлда хөрмәтле зәвеҗләренең чын мәгънәсе белән юлдашлары булганнары өчен, мәрхүм Принсның вафатыннан соң да шул ук химая һәм шәфкать таратуны дәвам иткәннәр һәм шул рәвешле нәҗиб нәселнең бөтен гүзидәлеген[3] лаеклы сурәттә гәүдәләндергәнен белдергән. Аллаһ үзеннән разый булсын.*

*Хөрмәтле остазыбыз белән сөйләшә идек. Аңлатты:*

*– Хәзерге хәлемдә дәрдем көтепханәдән ерак булуымдыр. Хәлбуки атнада берничә мәртәбә көтепханәгә барып, берничә сәгатемне анда үткәрергә телим. Бу сәбәпле язу язуны өмет итәм. Фәкать бу эшне башкару өчен йә хастәханәне фида итеп көтепханәгә якын бер урында урнашу һәм шулай итеп бирелә күргән һәм күрергә мохтаҗ булган дәвалану һәм багылудан мәхрүм булу, яки көтепханәне фида итеп бирелә эшсез утыру тиеш була. Белмим, бу ике ихтыяҗны канәгатьләндерү мөмкин булырмы?.*

*Бу сүзләр җитмешеннән узган, ягъни онын иләгән һәм иләген асып куйган бер олуг галим вә мөтәфәккирнең сүзләре иде.*

*Эшләү, эшләү, даимән эшләп тору, ахырына кадәр эшләү һәм файдалы булу – Муса Җаруллаһның иң зур шигаредер.*

*Аның өчен бу бик самими булган теләген ап-ачык аңлатты һәм бу дәрткә бер чара табуны бездән көтте.*

*Бу дәрткә чара табу безнең кулыбыздан килми иде.*

---

[1] нәҗиб – тәрияле гаиләдән булган кеше; аксөяк.

[2] зәвеҗ – өйләнгән ир; хатын-кызның ире.

[3] гүзидә – сайланып алынган; аерымланган.

*Фәкать бу язуны күргән һәм укуын өмет иттегемез Принсес Хәдиҗә ханымәфәнде хәзрәтләренең бу бик самими һәм бик гольви*[1] *теләк вә омтылышын тәэмин итәчәк бер чара табуын үтенәбез һәм рәхимлек итүен ялварабыз.*

*Остаз Муса Җаруллаһның теләгәне – бу ел кабат хаҗга чыгу, соңыннан Рауза-и мотаһһараны*[2] *зиярәт итү, соңыннан мәмләкәтебезгә*[3] *кайтудыр.*

*Үзе әлегә кадәр мөгаен унбиш тапкыр хаҗ кылган һәм Раузаи мотаһһараны зиярәт иткән…*

*Ягъни дини бурычларын кат-кат үтәгән…*

*Моңа карамастан хаҗка чыгарга теләвенең, әлбәттә, бер мәгънәсе бар иде. Фәкать бу мәгънәне аңлау кыен түгел ки…*

*Исламның бу ярты гасырлык хезмәтчесе, гомере төкәнгән булса, исламның туган һәм пәйгамбәрнең яшәгән җирләрендә соңгы сулышын алу, пәйгамбәрнең янәшәсендә урынлашып хозур һәм кайгырту эчендә Аллаһка кавышу өметендәдер. Шаядь гомере төкәнмәгән булса, исламның туган һәм пәйгамбәрнең яшәгән йортын кабат зиярәт итеп яңа илһамнар алу һәм яңа бер кызулык белән исламга хезмәт итәргә теләвендәдер.*

*Безнең бөтен теләгебез, бөтен өметебез – гомеренең озын булуы һәм аның сыйххәт вә сәламәтлек эчендә исламга хезмәтен дәвам итүедер. Чөнки ислам галәме, ислам фикеренең бүген йөзен агарткан бу кыйммәтле гыйлем һәм фикер адәменең хезмәтенә мохтаҗдыр.*

*Җәнабы Хакның аңа озын гомерләр һәм сәламәтлекләр насыйп итүен теләп, Фәхрел-мөхаддәрат Принсес Хәдиҗә Габбас Хәлим хәзрәтләренә шөкерләребезне белдерүне вазифа санап һәм Җәнабы Хакның һәр хәл һәм囡 эштә үзен уңышлы әйләвен ялварабыз»*[4].

---

[1] гольви – югарылыкның соң дәрәҗәсендә булган.

[2] Рауза-и мотаһһара (Пакь кыйлынган гөлбакча) – пәйгамбәребез Мөхәммәтнең Мәдинәдәге ханәсе һәм кабере.

[3] Мәмләкәтебезгә – илебезгә, ягъни Төркиягә.

[4] Musa Cârullah’la Mısırda bir mülâkat. Yeni Selâmet. 3 Ağustos 1949. Cilt IV. Sayı 24–98. S.6–7.

Инде яңадан Фәүзия ханым Догрул хатирәләренә әйләнеп кайтып, анда язылганнар белән танышуыбызны дәвам итик: «*Мин Истанбулда булганда каенэнем мөхәррир Гомәр Рыза Догрул бәй Мисырга барган иде. Муса әфәндене дә берничә мәртәбә зиярәт иткән. Тәмам сәламәт хәлендә күрүе, хәтта китаплыкларда эшләргә теләве, әмма барып-кайтып йөрер өчен бер арабага*[1] *ихтыяҗы булганын сөйләгән. Гомәр Рыза бәй Истанбулда чыгарган «Selamet» журналында бөтен докторлар хәятеннән өметләрен өзгән хәлдә Муса әфәнде 7 ай эчендә терелеп, сәламәт бер хәлдә яшәп ятуын белдергән эчтәлекле бер мәкалә дә язган иде.*

*49 елның август аенда Истанбулдан Искәндәриягә бардым. Мәүсем*[2] *җәй булганга, принсес Искәндәриядә иде. Аны зиярәт иттем һәм Муса Җаруллаһның хәле яхшыруын, китапханәләргә йөреп эшләү теләгендә булуын әйттем һәм бер араба сорадым. Принсес остазның хәяткә кабат кайтуына бик шатланды. Үзенә бер автомобиль хаслаулары өчен Каһирәдәге кятибләренә телефоннан шалтыратачак иде…*

*Каһирәгә кайткан вакытымда беренче эшем Муса әфәндене зиярәт итү булды. Зәгыйфьлеге белән бергә, сәламәтлеген яхшы дип таптым. Үзе дә, тормышыннан разый булуы белән бергә, соң дәрәҗәдә бик нык җаны авыртуын сөйләгән иде. Өстеннән торып сәбәбен белергә теләвемнән аңлашылды ки, «Мәлҗәъ»тә озак торуы белән принсесны һәм үзенә ярдәм иткән башка кемсәләрне соң дәрәҗә алҗыткан булуын аңа кайбер фетнәче якташларыбыз сиздергәннәр. Мин үзенең нәкъ киресе булуын аңлатып тынычландырдым, һич тә кайгырмавын үтендем һәм: «Тагын йөз ел яшәсәгез дә принсес тик горурланачак һәм һәр теләгегезне үтәячәк»,– дидем. Моңа җавап итеп үзенең тынычлануын белдерде һәм кемсәнең сүзенә колак салмаячагын вәгъдә итте һәм мине капкага кадәр озатты. Мәгәр бу соңгы күрешүебез булган икән*».

[1] араба – машина.

[2] мәүсем – ел фасылы, сезон.

## Муса әфәнденең соңгы көне

Чыннан да, олуг галимнең әҗәл сәгате инде бик якынайган була. Хаҗлар кылып, Рауза-и Мотаһһараны зиярәт итү аңа инде насыйп булмый. Өч айдан Муса әфәнденең җир йөзендә үткәрәчәк соңгы көне килеп җитә, йөрәге соңгы мәртәбә тибә, соңгы сулыш алына... Гомере дәвамында Раббым дип, динем дип, өммәтем дип аң, мәгърифәт һәм хакыйкать нурлары белән дөнья караңгылыгын яктыртып, үзен соңгы күзәнәгенә кадәр фида кылган бөек шәхеснең газиз җаны 1949 елның 25 октябрендә[1] Аллаһ тәгаләнең мәрхәмәте белән кавыша. Бу турыда Фәүзия ханымның Баттал-Таймаска язып җибәргән хатирәләрендә түбәндәгеләр язылган:

«*Үлеме.*

*Аен хәтерләмим (26 октябрь булачак: А.Б.Т)[2], берәү ирем Нафизгә телефоннан шалтыратып, Муса әфәнденең сәгать 15 тә бу хәяткә күзләрен йомганлыгын һәм икенде намазыннан соң җиргә биреләчәге турында хәбәр итте. Вакыт бик тар иде. Ирем беренче мөмкинлек белән шәһәргә барып җитте. Телефоннары булган дусларга һәм Төркия консуллыгына телефон белән хәбәр бирдем. Җан биргән минутта бары тик әзһәрле дусларыннан Лаз Мөхәммәт әфәнде булган икән. Бу зат мөхтәрәм мәрхүмне ефәк кәфенгә ураганын исе китеп сөйләде. Принсларның гаилә мазарына кирәк булса күчерелерлек бер шәкелдә күмгәннәр. Кабергә иңдерелгәндә искә алынган Йосыф Вәлишаһ, ирем Нафиз Догрул, якташларыннан мөдәррис Хәмзә Таһир һәм, мөгаен, Галимҗан Идриси булганнар.*

*Калган әйберләренә ни булганын белмим. Китапларын Әнкарага, Төркиянең Каһирә консуллыгына җибәргән. Азәрбайҗанлы искә алынган Али Хәйдәр әфәнде Милли китапханәгә биреләчәк бу китапларны Төркиягә үзе илткәнен әйткән иде.*

*Кадерле галимебез Муса Җаруллаһ Бигигә бу кадәр яхшылыклар кылган принсес Хәдичә дә инде рәхмәтле Рахман белән кавышкан*».

[1] Uralgiray. Önsöz, s. XX.

[2] Габдулла Баттал-Таймасның өстәмәсе.

Мисырда чыгып килүче иң мәртәбәле «әл-Әһрам» гәзите 1949 елның 29 октябрь санында Муса Җаруллаһның җеназасы Каһирәнең Сәйидә Нәфисә исемле мәчетендә укылуы һәм олуг галимнең Мисыр падишаһлары дәфен кылына торган Хидивләр зираты дип аталган борынгы мазарда күмелүе турында игълан бастыра.

Фәүзия ханымның үзенә язып биргән бу хатирәләр белән уртаклашканнан соң, Баттал-Таймас Муса әфәнденең вафаты һәм җеназасына кагылышлы кайбер килешсез хәлләр турында да язып калдырган: «*Фәүзия ханым Әл-Әзһәрнең Төрек төркеменең шәехе булган, асылы белән чиркәс шәех Габделхәмидкә телефон белән хәбәр биргәннән соң, бу шәехнең җеназага бармавы бер урында торсын, хәтта төрек шәкертләренә дә хәбәр бирмәгән; бары тик университет мөдәррисе казанлы Хәмзә Таһирга җиткерү белән канәгатьләнгән. Ул көннәрдә Төркия гражданлыгында булган Муса Җаруллаһның үлүе турында хәбәрдар ителгән хәлдә, Төркия консуллыгы да һич игътибар күрсәтмәгән һәм бер генә булса да вәкил җибәрмәгән. Ярый әле мәрхүмнең Әнкара Милли китапханәсенә тапшырылуын васыять иткән китапларны кабул итүгә һәм Төркиягә озатылуына комачауламаган...*

*Бөтен бу күңелсез хикәядән бер нәтиҗә чыгаруны зыялы укучыларыма тапшырам да, үзем тынам*».

Олуг галимнең вафаты турындагы хәбәр тиз арада Төркиягә дә ирешә. Җирле матбугат чараларында аның истәлегенә мәрасим мәкаләләре басыла башлый. Галимнең дөньядан бу кадәр гаҗиз булып, бер мескен хәлендә китүенә җаны әрнегән Шир Әмир Оглу әфәнде «*Мәрхүмнең кырык еллык әхбабеннән*»[1] язмасында мондый сүзләр язып калдырган: «*Безнең дә олы хата һәм гафләтебезнең һәм сәяси җаһиллегебезнең нәтиҗәсе буларак большевиклык үсеш алмаган булса иде, бүген камилләшү юлы белән мөстәкыйльлегенә ирешәсе булган бөек милләтебезнең бу иң бөек галименең җеназа һәм дәфен мәрасимендә мәлҗәэнең*[2] *бер-ике хезмәткәре белән бары тик*

[1] әхбабеннән – яраткан дустыннан.

[2] мәлҗәэнең – приютның.

*ике төрек булмыйча, мәрхүм ун меңнәрчә төрекнең катнашуы һәм бөек ихтирамы белән аеруча соңгы көннәрендә бик сагынылган үз илендә дәфен ителгән булыр иде»*[1].

«Yeni Selâmet» журналында «Бөек остаз Муса Җаруллаһ 25 октябрьдә Аллаһның рәхмәтенә кавышты» исемле мәрасим мәкаләсе чыга: «*Ислам галәменә һәм төрек милләтенә килгән зур югалту сәбәпле кайгыбызны белдерәбез.*

*Ислам галәме хакыйкатән зур бер югалтуга юлыкты һәм бөек мөтәфәккирләреннән, бөек мөҗтәһидләреннән берсен югалтты. Югалтылган зат: соңгы гасырда ислам фикеренең йөзен агарткан бөек шәхес Муса Җаруллаһтыр. Ярты гасырдан артык бер заман ислам белеменә хезмәт иткән, ислам фикерен югарыга күтәргән, ислам яшәешен җанландырган бу асыл, мөбарәк шәхес тә арабыздан китеп Аллаһның рәхмәтенә кавышкан һәм безләрне үксез һәм матәмнәк*[2] *калдырган.*

*Гәрчә аның бу дөнья йорты белән алыш-бирешен туктатырга теләве былтыр бередән Мисырга китүеннән һәм аннан Хиҗазга барып соңгы көннәрен ислам диненең нигезләүчесе һәм әйдәп баручысы булган хәзрәти пәйгамбәр әфәндебезнең пакь янәшәсендә үткәрергә теләвеннән билгеле иде. Үзе дә моны якын дусларыннан яшерми иде. Хиҗазга киткәннән соң, дәрман таба алса кабат безгә киләчәген һәм безнең белән бергә яшәячәге турында әйтә иде. Фәкать аның Хиҗазга барудан максаты – анда, ислам нурының дөньяны беренче мәртәбә яктырткан җирдә һәм ислам пәйгамбәренең янында җан бирергә җыену иде. Бу аның һәр ишарәсеннән һәм һәр хәленнән аңлашыла иде.*

*Максаты һәм һәдәфе*[3] *яшәешенә туры килә иде. Гомерен исламияткә вакыф кыйлган иде. Ишен-баласын һәм бөтен барлыгын бу эшкә фида кыйлган иде. Яралы калебен һәм яра-*

---

[1] Emir oğlu, Şir. Күрс. мәк.

[2] матәмнәк – берәүнең үлеме аркасында кайгы-хәсрәт кичерү хәле.

[3] һәдәф – атканда төбәп ата торган мая, мишень; нинди дә булса эшнең көтелгән нәтиҗәсе.

*лы калебенең бөтен илһамнарын бу юлга биргән иде. Бөтен хәяте бәлаләр, кайгы-хәсрәтләр һәм борчулар эчендә үткән иде. Фәкать бөтен боларга һаман шул идеалга ирешергә тырышуы белән каршы тора иде. Җирен, йортын, рәхәтен, керем-чыгымын, бала-чагаларын, булган һәрнәрсәсен һаман бу юлда, һаман шул идеал кояшына, һаман шул хакыйкать нуры хакына фида иткән, һаман шуның юлын тоткан, һаман аның эзеннән йөргән, аеруча гомеренең һәр биргәнен шуңа сарыф иткән иде. Соңында да бөтен бу фидакярьлекләренең нәтиҗәсе буларак бөтен теләгәне – аның пакь янында, аның туфрагына күмелү иде!*

*Бу нинди ис китәрлек һә югары бер сөю, нинди чиксез һәм кыю бәйләныш иде!*

*Аның туфрагы эчендә күмелү!*

*Әйтергә тели ки: «Йә Рәсүлүллаһ! Менә сиңа бер гомер ки – синең юлыңда йөргән, синең динең хакына гамәл кылып, синең динеңнең игелекләрен тарату белән шөгыльләнгәндә өзелгән. Һәм менә ниһаять җан һәм мал, бала вә иш, ил, йорт – һәммәсен фида итеп сиңа сыенган, синең туфрагыңа сыенган, анда хозурга кавышуны сагынгандыр!. Кабул ит!. Йә Рәсүлүллаһ!.»*

*Муса Җаруллаһ хәяте бу иде, һәм бер елдан артык бер замандыр элек һаман Хиҗазга баруны сагынуының һәдәфе моннан гыйбарәт иде.*

*Аның Рәсүлүллаһка тәкъдим итәчәк әдәби һәм гыйльми бүләк һәм мирасы бик зур иде. Һәм, чыннан да, Рәсүлүллаһның рухы аны сөенеп һәм ризалык белән каршы алачак иде.*

*Муса Җаруллаһның Мисырда үлүе һәм Гафифи каберстанында күмелүе, иманам ки, бу максатына һәм һәдәфенә киртә булмаган. Инанамын ки, Рәсүлүллаһның рухы аны каршыларга чыккан һәм аңа янына урын биргән. Инанам ки, Рәсүлүллаһның рухы аны Мисырдан каршы алырга чыккан һәм аны бу рәвешле кадерләгән вә хөрмәтләгән.*

*Фәкать ул – тыйнак адәм, Рәсүлүллаһның үзен Мисырдан каршылавына мөмкинлекне бирерме?*

*Кадер аны шул ук урында екмаган булса иде, ул, хәзрәте Пәйгамбәр әфәндебезнең аяк очында җан бирүне җанга игелек итеп белмәс идеме?*

*Фәкать кадер Муса Җаруллаһның кулында түгел иде, кадер аны Мисырда җан бирүенә әмер ителгән, ул да җан биргән һәм Мисырда хәзрәти пәйгамбәр әфәндебез тарафыннан каршыланып Харәм-е шәрифкә китерелгән.*

*Мисырда калды шәһитнең вөҗүд-е фанисе,*
*Рәсүлгә ирде, фәкать рух-ы җавиданесе.*

*Муса Җаруллаһ бу кадерләүгә лаек бер адәм иде. Чөнки чынбарлык һәм шәрәфле бер мөселман иде. Чөнки ислам фикерен югарыга күтәргән, исламның һәр дәвердә хитаб иткән[1] бер дин булуын үзенең фикернең югарылыгы белән исбат итте. Чөнки хәяттә бер мөселманның дини кайгыртуда кичерә алачак һәр авырту һәм һәр җәфаны үткән, яраланган, канатлары сынган, фәкать даимән исламияткә хезмәт иткән, даимән исламның игелекләреннән илһам алган, даимән эшләп торган. Исламның мәдәни, гыйльми, тормышка караган һәр яссылыкта иң бөек раһбәре булуын исбат иткән әсәрләрен язган, исламиятнең бүгенге зиһенен, бүгеннең караш һәм уйлавын тәэмин итәчәген белдергән, бу юлда йөзләрчә әсәр һәм рисаләләр язган һәм соңында, Пәйгамбәр-и зишан[2] әфәндемезнең туфрагына күмелеп, хәят белән хушлашырга теләгән.*

*Бүген бу юлда, бу кимәлдә, бу куәт һәм кодрәттәге мөселманнар никадәр сирәк очрый. Фәкать Муса Җаруллаһ бу сирәк очрый торган кемсәләрнең иң өстеннәреннән берсе иде.*

*Гомере буе кайгырткан нәрсәсе Аллаһ ризалыгы иде, вөҗдан хозуры иде. Әсәрләрен, ни кылып дулса да, үз исәбенә бастырыр һәм таратыр иде, яки хәер оешмасына вакыф итәр иде.*

*Гомерендә бер әсәреннән матди бер мәнфәгать көтмичә, бары тик әсәрләренең таратылуыннан һәм укылуыннан рәхәт тоя иде. Бу төр кешеләр инде юкка чыктылар кебек. Фәкать Муса Җаруллаһ мондый бер адәм иде һәм берәүнең*

[1] хитап иткән – вәгазьләгән, үгетләгән.

[2] Пәйгамбәр-и зишан – данлыклы пәйгамбәр.

*нинди дә булса әсәрен бастыруына комачау итү өчен бөтен әсәрләрен турыдан-туры һәм шәхсән үз тарафыннан бастырачагы турында әсәрләрнең эчтәлеге башына куя иде.*

*Аллаһ ризалыгына ирешүне бу кадәр кайгырткан бер кешенең пәйгамбәре тарафыннан шатлык һәм ризалык белән каршы алыначагы шөбһәләндерә аламы?*

*Дөньяның иң саф әхлаклы, иң югары рухлы кешесе иде. Коръән әхлагын тормышка ашырыр һәм ашыртыр иде. Намуслылыгы һәм әхлакый пакьлеге, барына канәгать булуы һәм затлылыгы акылны хәйран калдырырлык дәрәҗәдә иде, чын мәгънәдә ислами маһиятьтә*[1] *иде. Вәлидәмез хәзрәти Гайшәдән:*

*– Хәзрәти пәйгамбәр ничек яши иде? – дип сораган чакта ул:*

*– Аның яшәеше Коръәннең үзе иде! – дигән иде.*

*Хәзрәти остазның яшәеше дә нәкъ шундый иде һәм нәкъ шундый булганы аркасында соңгы сулышын пәйгамбәр-и зишанның янында алу, аның хозурында соңгы көннәрен яшәү һәм, ниһаять, аның хак-ы гыйтырнакенә*[2] *кавышуны тели иде.*

*Үткән рамазан бәйрәмендә Мисырга баруымның тик аны күрер өчен икәнен аңлаган остазны иң яхшы хәлдә күрүемә мин бәхетле идем. Сыйххәте әйбәт, кәефе әйбәт иде. Йөреп тора иде һәм күргән дәва һәм игътибар турында шатланып сөйли иде.*

*Аллаһ аңа Мисырда Принсес Хәдиҗә ханымәфәнде хәзрәтләре кебек бер яклаучы җибәргән иде. Принсес хәзрәтләре аның белән аралаша иде, аның сыйххәт һәм сәламәтлектә даим булуы өчен кирәк булган һәрнәрсәне тәэмин итә иде, аның ашау-эчүенә, рәхәт һәм хозур эчендә яшәвенә ифрат зур әһәмият бирә иде. Хәятеннән канәгать иде һәм миннән үтенгән иң соңгы нәрсә – бәйрәмдә күргән лотыф*[3]

---

[1] маһиять – биредә: исламның табигый хәле, табигый сыйфаты; исламның чыны, үзлеге.

[2] хак-ы гыйтырнакь – хуш исле туфрак.

[3] лотыф – киң күңел белән кылынган ярдәм.

*һәм гатыйфәт*[1] *өчен Принсес хәзрәтләренә минем каләмем белән шөкерләрен җиткерү иде.*

*Бәйрәмдә кадерле остаз Галимҗан Идрисинең табыны әтрафында җыелышып бәйрәм пылавы ашаган идек. Әман. Йә Рабби, ул көн никадәр яхшы иде; никадәр шатлыклы һәм никадәр кәефле иде. Сөенә-сөенә хатирәләрен сөйли иде һәм барыбыз да аның сөенечен, шатлыгын сау-сәламәт булуның галәмәтеннән санап, һаман аны тыңлый идек. Никадәр татлы итеп сөйли һәм омтылышларын никадәр матур аңлата иде.*

*Ул көнне үзе белән хушлашырга мәҗбүр идем һәм озак бер заман яшәячәгенә инана идем. Шулкадәр нык һәм шат иде. Мәгәр вакыт бик якын булган икән, һәм ике-өч айдан бу дөньяга видагъ итәчәк*[2] *булган икән!..*

*Аллаһ рәхмәт әйләсен. Бик бөек бер адәм һәм тагын күп әсәрләр язачак тиңдәшсез кешене югалттык.*

*«Selâmet»һәм «Selâmet» гаиләсе аны югалтудан кара кайгыга калды. Инде безгә төшкән эш – аның хәятен һәм хезмәтләрен язудыр. Без дә бу вазифаны кулыбыздан килгән кадәр иһмаль итмәячәкбез*[3].

*Бөтен ислам галәменең кайгысын уртаклашабыз. Чөнки бөтен ислам галәме бу тарихта сирәк очрый торган гүзидә шәхесне югалтты.*

*Бөтен ислам гыйлем галәменең кайгысын уртаклашабыз. Чөнки ислам гыйлем галәме әйтеп бетергесез югалтуга юлыкты.*

*Мәрхүм остазыбыз Муса Җаруллаһ җәннәтләрендә урын алгач үксез калган ислам галәмен аның дәрәҗәсендәге бөекләрдән мәхрүм итмәвен Аллаһтан үтенеп сорыйбыз»*[4].

---

[1] гатыйфәт – илтифат, ягымлылык.

[2] видаг итәчәк – бәхилләшәчәк.

[3] иһмаль итмәячәкбез – салкын карамаячакбыз, игътибарсызлык күрсәтмәячәкбез.

[4] Büyük Üstad Musa Cârullah 25 Ekımde Allahın Rahmetine Kavuştu. Yeni Selâmet. 1949. Cilt IV. Sayı 36–104. S.10–11.

Инде Муса әфәнденең кабер ташындагы язу турында да сүз әйтергә кирәк. Үзенең китабында Баттал-Таймас остазның кабере янында төшереп алынган бер фото китерә. Фотосурәттән аңлашылганча, Муса әфәнденең кабере төрбәдә урнашкан һәм аның янәшәсендә башка каберләр дә барлыгын чамаларга мөмкин. Кабер ташындагы язуга килгәндә, фотосурәтне яхшылап тикшерә алган Баттал-Таймас бу турыда күрсенеп мондый сүзләр язган: «*Күренеп торганча, бу кабер ташындагы язуда Муса Җаруллаһның «Бөек галим» (әл-Галим әл-җәли) һәм төрек (әт-Төрки) булуы теркәлгән. Монысы яхшы. Әмма кайдан ул? Бу юк. Төреклек бик киң бер дөньядыр. Үзе бу киң дөньяның кайсы җиреннән иде? Дөрес, остазыбыз бер төректер, әмма һәр нәрсәдән әүвәл, килеп чыгышы ягыннан бер казанлы иде, бездән иде. Язуда моны белдерергә кирәк иде. Әйтик, Казанда үлгән бер гарәп галименең кабер ташындагы язуга тик Әл-Гарәби*[1] *сүзе язылмыйча, мотлакан Әт-Туниси, Әл-Җәзаъири, Әт-Тараблүси, Әл-Мисри кебек, туган иленең исеме дә язылачак иде. Гарәп катгый сурәттә моңа игътибар итмичә булдыра алмас иде. Үзе дә асылда бер казанлы булган Галимҗан Идриси остазыбыз Әт-Төрки сүзе янына бик тә урынлы булган Әл-Казани сүзен дә кушып яздырта ала иде. Хөрмәтле илдәшем мине гафу итсен: бу юлдагы тәнкыйтемне бик йомшак бер шәкелдә белдерәчәкмен: юкка тырышканнар!*»

[1] Әл-Гарәби – Гарәби, ягъни чыгышы белән гарәп кавеменнән.

# Йомгак урынына

Муса әфәнденең тормыш юлын һәм эшчәнлеген тасвирлауга багышланган язмам шуның белән тәмам. Кулымнан килгән кадәр һиммәт күрсәтеп, үземдә еллар дәвамында тупланган чыганакларны кулланып, аларның бер өлешен укучылар игътибарына тәкъдим итеп, олуг галимебез, бөтен ислам дөньясында танылган һәм ихтирам ителгән ислами фикер иясе Муса Җаруллаһ әфәнде Бигиевнең тәрҗемәи хәлен бәйнә-бәйнә барлап бәян итәргә тырыштым.

Әлбәттә, биредә китерелгән мәгълүмат тулы түгел. Галим биографиясенең кайсы гына өлешен, кайсы гына чорын алсаң да, һәммәсендә дә әле өйрәнелмәгән ак таплар бихисап. Шулай да, татар милләтенең йөзе кашы, татар цивилизациясе таҗының очына куелган асылташ булган Муса әфәнде Бигиевкә һәм аның күргән-кичергәннәренә караган бу кадәр генә булса да мәгълүмат татар халкы тарихында үз урынын табар дип өметләнеп калам.

Сүземне замандашларыбыздан булган ике зур галимнең Муса әфәнде турында әйткәннәре белән тәмамлыйм. Төрек галиме, берничә ел дәвамында Төркия Җөмһүриятенең Дин эшләре министрлыгын җитәкләгән, соңыннан Төркия мөфтие булган Мәхмәт (Мөхәммәт) әфәнде Гөрмәзнең[1] фикеренчә, Муса әфәнде Бигиев Җәмалетдин Әфгани, Мөхәммәт Габдүһ

[1] Мәхмәт Гөрмәз (1959 елны Төркиядә, Газиантеп вилаятендә туган) – 1987 елда Әнкара Университетының илаһият факультетын тәмамлый, хәдис белеме буенча аспирантурага керә. 1988 елда Каһирә университетында тикшеренүләр үткәрә. 1995 елда Сөннәт һәм хәдисләрне аңлату һәм шәрехләү методологиясе мәсьәләсе буенча докторлык диссертациясен яклый. 2006 елда профессор дәрәҗәсен казана, 2010 елда Төркия Диянәт министрлыгы җитәкчесе, ягъни, мөфти буларак билгеләнә, 2017 елга кадәр шул хезмәттә булып, пенсиягә китә. Муса Бигиев мирасын өйрәнүче төрек галимнәреннән берсе, аның әсәрләрен төрек теленә тәрҗемә итеп бастыра.

кебек галимнәрдән күпкә өстен тора: «*Аның матди мөмкинлекләре чикле булганга күрә генә бүгенге тарих фәне Муса Бигиев турында түгел, ә Җәмалетдин Әфгани, Мөхәммәт Габдүһ турында сүз йөртә… Муса әфәнденең мирасы өйрәнелсә иде, соңгы елларда дөньяның һәр почмагында үзенең барлык ялгышу-саташулары белән дан тоткан ваһһабилык тәгълиматы кебек чирнең дәвасы тиз табылыр иде. Башкача әйткәндә, Муса әфәнденең фикерләре, ачышлары белән таныш булган кеше беркайчан да мондый вак һәм сай тәгълиматлар кысалары белән үзен чикләтергә юл куймаячак*».

Фәлсәфә докторы Тәүфыйк әфәнде Ибраһим[1] болай ди: «*Татар халкыннан үз вакытында бөтендөнья ислами фикерен яңартучыларның иң бөеге булган дөнья күләмле фикер иясе чыккан. Татарлар, әлбәттә, моның белән горурлана алалар. Мин моңарчы да әйтә килдем, алга таба да әйтеп торачакмын: әгәр Русия мөселманнары,– беренче нәүбәттә сүз татарлар турында бара,– әгәр дә татарлар бөтен ислам дөньясына чын ислам диненең нинди булырга тиешлеген, ягъни аның иң алдынгы булуын, камил акыл ияләре өчен иң ятышлы, башкаларга карата иң түземле һәм аралашу өчен иң ачык дин булуын татарлар күрсәтмәсәләр, бу эшне кайдан булса да башка җирдән, башка милләттән көтмәгез! Мөселман булмаган халыкларга һәм, аеруча, мөселманнарның үзләренә егерме беренче гасырда исламиятнең нинди булырга тиешлеген күрсәтү вазифасын бары тик сез генә башкарып чыга аласыз! Башка беркемнән дә көтмәгез! Моның өчен сездә бөтен шартлар тудырылган. Олуг дин галимнәренең мирасына иясез. Алар арасында Муса Бигиев иң югарысыдыр. Менә шушы мирасны алып, башкаларга ирештерергә кирәк*».

[1] Тәүфыйк Ибраһим (Тауфик Кямил Ибраһим; 1947 елда Сүриядәге Җәбла шәһәрендә туган) – совет һәм Россия фәлсәфәчесе, ислам белгече, классик гарәп-мөселман фәлсәфәсе белгече. Фәлсәфә фәннәре докторы (1984), профессор. Россия Фәннәр академиясе Шәрык белеме институтында гарәп һәм ислам тикшеренүләре үзәгенең баш фәнни хезмәткәре. Россия ислам динен өйрәнүчеләр җәмгыятенең рәисе.

Ошбу китапта язылганнар укылган саен, укучыларның күңелләренә килгән самими хисләр кузгалган саен, Аллаһ тәгаләнең мәрхәмәте илә кабул ителеп, Муса әфәнденең рух шәрифләренә һәм аның белән бергә телгә алынган һәммә мәрхүмнәрнең рух шәрифләренә дога булып ирешеп торсын иде.

رَبَّنَا اغْفِرْ لَنَا وَلِإِخْوَانِنَا الَّذِينَ سَبَقُونَا بِالْإِيمَانِ

*Раббанә гъфир лә-на вә ли-ихванина әл-ләзинә сәбәку-на би-л-ийман*

***Раббыбыз, безне һәм иман белән бездән алда булган кардәшләребезне ярлыкагыл***[1]

*Айдар Хәйретдинов. Казан, апрель-июль, 2022.*

[1] Коръән, 59:10.

# II бүлек.
# Муса Бигиевнең искә алынган китапларының нәшер ителү тәртибендә төзелгән исемлеге

**1905**

1. «Тарих әл-Коръән вә әл-мәсахиф» (СПб)[1].

1906

2. «Русия мөселманлары иттифакының програмы» (СПб.)[2].
3. «1906 сәнә 16–21 августда иҗтимаг итмеш Русия мөселманларының нәдвәсе» (Казан, 1906).
4. «Русия мөселманнарының Өченче нәдвәсе» (Казан).
5. «Русия мөселманнарының Өченче нәдвәсенең забыт җәридәләре» (Казан).
6. «Нижний Новгородта вакыйг улан Русия мөселманлары өченче нәдвәсенең мокарраративы (16–21 август, 1906)» (Казан).

**1907**

7. «Китабу әш-Шатыбийәти» (Казан).
8. «әл-Әхруфу әл-Куръәнийә вә таърихуу әл-кыйраъәти» (Казан)[3].
9. «әл-Лүзүмийәт» (Казан).
10. «Әдәбийат гарәбийә илә голүм исламийә» (Казан)[4].

---

[1] Китап: 1) 2017 елда рус теленә тәрҗемә ителеп басылды: Бигиев, Муса. История Корана и его сводов / Муса Бигиев; пер. с арабск.; под общ. ред. Д. В. Мухетдинова – М.: ИД «Медина», 2017.– 104 с.; 2) Россия Федерациясе мөселманнары Диния нәзарәте (РФ МДН) тарафыннан гамәлгә ашырылган «Исламская мысль в России: возрождение и переосмысление» (ИМР) проекты кысаларында Д. В. Мөхетдинов редакциясендә «Медина» нәшрият йортында басмага әзерләнә. (Алга таба: ИМР проекты кысаларында…).

[2] Китап ИМР проекты кысаларында «Медина» нәшрият йортында басмага әзерләнә.

[3] Китап ИМР проекты кысаларында, А. Хәйретдинов тарафыннан рус һәм татар телләренә тәрҗемә ителеп, Д. В. Мөхетдинов редакциясендә «Медина» нәшрият йортында басмага әзерләнә.

[4] Китап: 1) 2000 елда татар теленә тәрҗемә ителеп басылды: Бигиев М. Җ. Гарәп әдәбияты һәм ислам фәннәре / Тышлык, төзелеше, кереш мәкалә, тәрҗемә һәм искәрмәләр: Хәйретдинов А. Г.– Казан: Иман, 2000.– 127 б.; 2) 2014 елда рус теленә тәрҗемә ителеп басылды: Бигиев, М. Д. Избранные труды / Муса Джаруллах Бигиев; [сост. и пер. с османского яз., введ., сн. и коммент. А. Хайрутдинова].– Казань: Татар. кн. изд-во, 2014. 398 с.; 3) ИМР проекты кыса-

**1908**

11. «Китабу гакыйләти атраби әл-касаъиди фи әсна әл-макасыйд» (Казан).
12. «Китабу таһарати әл-гарәби» (Казан).
13. «Мәвараэннәһердә сәйахәт» (Казан).

**1909**

14. «Әл-Моваттаъ» (Казан).
15. «Шәригать ничүн роэяти игътибар итмеш?» (Казан)[1].
16. «Тәсъхыйхы рәсме хатты Коръән» (Казан)[2].
17. «Дәлилүн сарихун фи нөзүли әл-Мәсихи» (Казан).
18. «Китабу әл-мөвафәкати ли-имами әл-хафизи әл-мөфассири әл-фәкыйһи әл-усулийи әш-шәйхи Аби Исхак Ибраһим ибни Муса әш-Шатыби радыйа Аллаһу ганһу» (Казан).
19. «Әл-Мөвафәкать мөкаддимәсе» (Казан)[3].

---

ларында, А. Хәйретдинов тарафыннан рус һәм татар телләренә тәрҗемә ителеп, Д. В. Мөхетдинов редакциясендә «Медина» нәшрият йортында басмага әзерләнә.

[1] Китап: 1) 2014 елда рус теленә тәрҗемә ителеп басылды: Бигиев, М. Д. Избранные труды / Муса Джаруллах Бигиев; [сост. и пер. с османского яз., введ., сн. и коммент. А. Хайрутдинова].– Казань: Татар. кн. изд-во, 2014.– 398 с.; 2) ИМР проекты кысаларында, А. Хәйретдинов тарафыннан татар һәм рус телләренә тәрҗемә ителеп, Д. В. Мөхетдинов редакциясендә «Медина» нәшрият йортында басмага әзерләнә.

[2] Китап: 1) 2020 елда татар теленә тәрҗемә ителеп басылды: Муса Бигиев. Тәсхыйх рәсми хатти Коръән (Коръәннең язылыш сурәтен дөресләү) / ис. тат. тел. тәрҗемә, кер. сүз, астөшерм. һәм аңлатм.– Р. Р. Ибраһимов.– Мәскәү: АНО Издательский дом «Йосеф Ибрахим» 2020.– 152 б.; 2) ИМР проекты кысаларында, А. Хәйретдинов тарафыннан рус теленә, Р. Ибраһимов тарафыннан татар теленә тәрҗемә ителеп, Д. В. Мөхетдинов редакциясендә «Медина» нәшрият йортында басмага әзерләнә.

[3] Китап: 1) 2001 елда татар теленә тәрҗемә ителеп басылды: Бигиев М. Җ. «әл-Муәфәкать» мөкаддимәсе / Татарчага тәрҗемә, кереш сүз: А. Хәйретдин – Казан: Иман, 2001.– 21 б.; 2) 2006 елда рус теленә тәрҗемә ителеп басылды: Бигиев М. Избранные труды: в 2 т. / Муса Бигиев; Сост. и пер. с осман. А. Хайрутдинова. Т. 2: Обращение к Великому Турецкому Национальному Собранию, Введение к трактату «Аль-Муафакат», Воззвание к мусульманским

20. «Ифадату әл-кирами» (Казан).

**1910**

21. «Кавагыйд фикъһийә» (Казан)[1].
22. «Диван-ы Хафиз тәрҗемәсе» (Казан)[2].
23. «Назымәтү әз-зүһр ли-имами Аби Мүхәммәд әл-Касим ибни Фирруһ әш-Шатыби радыйа Аллаһу ганһу» (Оренбург).
24. «Нүзһәтүән-натъри фи тәүдыйхи нөхбәти әл-фикри» (Оренбург).

**1911**

25. «Рәхмәт илаһийә борһанлары» (Оренбург)[3].
26. «Инсанларның гакыйдә илаһийәләренә бер назар» (Оренбург)[4].

---

нациям, Женщина в свете священных аятов благородного Корана.– Казань: Татар. кн. изд-во, 2006.– 256 с.; 3) ИМР проекты кысаларында, А. Хәйретдинов тарафыннан татар һәм рус телләренә тәрҗемә ителеп, Д.В. Мөхетдинов редакциясендә «Медина» нәшрият йортында басмага әзерләнә.

[1] ИМР проекты кысаларында, А. Хәйретдинов тарафыннан рус теленә тәрҗемә ителеп, Д.В. Мөхетдинов редакциясендә «Медина» нәшрият йортында басмага әзерләнә.

[2] ИМР проекты кысаларында Д.В. Мөхетдинов редакциясендә «Медина» нәшрият йортында басмага әзерләнә.

[3] Китап: 1) 1999 елда татар теленә тәрҗемә ителеп басылды: Бигиев М. Илаһи мәрхәмәтнең дәлилләре / Төзүче, төп текстның транскрипциясе, хәзерге татар теленә тәрҗемә һәм искәрмәләр А.Г. Хәйретдинов.– Казан: Казан ун-ты нәшрияты, 1999.– 196 б.; 2) 2005 елда рус теленә тәрҗемә ителеп басылды: Бигиев Муса. Избранные труды. В двух томах. Т. I / Сост., пер. с осман. введ. и примеч. А. Хайрутдинова.– Казань: Татар. кн. изд-во, 2005.– 336 с.; 3) 2022 елда рус теленә тәрҗемә ителеп басылды: Бигиев, Муса. Доказательства Божьей милости / Централизованная религиозная организация Духовное упр-е мусульман РФ; Моск.ислам. ин-т; Санкт-Петербургский гос. ун-т; под общ. ред. Д.В. Мухетдинова; пер. с тат.– осман и примеч. А.Г. Хайрутдинова.– Серия «Исламская мысль в России: возрождение и переосмысление».– М.: ИД «Медина», 2022.– 160 с.; 4) ИМР проекты кысаларында, А. Хәйретдинов тарафыннан татар теленә тәрҗемә ителеп, Д.В. Мөхетдинов редакциясендә «Медина» нәшрият йортында басмага әзерләнә.

[4] Китап: 1) 2005 елда рус теленә тәрҗемә ителеп басылды: Бигиев Муса. Избранные труды. В двух томах. Т. I / Сост., пер. с ос-

27. «Озын көнләрдә рузә» (Казан)[1].
28. «Сионизм» [Оренбург][2].

**1912**

29. «Халык назарына берничә мәсьәлә» (Казан)[3].
30. «Таййибәт ән-нәшр фи әл-гашр» (Казан)[4].
31. «Исламияттә кадер» [Казан].

---

ман. введ. и примеч. А. Хайрутдинова.– Казань: Татар. кн. изд-во, 2005.– 336 с.; 2) 2022 елда рус теленә тәрҗемә ителеп басылды: Бигиев, Муса. Взгляд на верование людей в божественное / Централизованная религиозная организация Духовное упр-е мусульман РФ; Моск.ислам. ин-т; Санкт-Петербургский гос. ун-т; под общ. ред. Д. В. Мухетдинова; пер. с тат.– осман и примеч. А. Г. Хайрутдинова.– Серия «Исламская мысль в России: возрождение и переосмысление».– М.: ИД «Медина», 2022.– 64 с.; 3) ИМР проекты кысаларында, А. Хәйретдинов тарафыннан татар теленә тәрҗемә ителеп, Д. В. Мөхетдинов редакциясендә «Медина» нәшрият йортында басмага әзерләнә.

[1] Китап: 1) 2005 елда рус теленә тәрҗемә ителеп басылды: Бигиев Муса. Избранные труды. В двух томах. Т. I / Сост., пер. с осман. введ. и примеч. А. Хайрутдинова.– Казань: Татар. кн. изд-во, 2005.– 336 с.; 2) ИМР проекты кысаларында, А. Хәйретдинов тарафыннан рус теленә тәрҗемә ителеп, Д. В. Мөхетдинов редакциясендә «Медина» нәшрият йортында басмага әзерләнә.

[2] Оренбургта басылган булуы ихтимал.

[3] Китап: 1) 2017 елда татар теленә тәрҗемә ителеп басылды: Хәйретдинов А. Г. Муса Бигиевнең «Халык назарына» исемле китабының аңлатмалы тәрҗемәсе. Казан, 2017.– 136 б.; 2) 2022 елда рус теленә тәрҗемә ителеп басылды: Бигиев, Муса. Некоторые актуальные проблемы нашего общества / Централизованная религиозная организация Духовное упр-е мусульман РФ; Моск.ислам. ин-т; Санкт-Петербургский гос. ун-т; под общ. ред. Д. В. Мухетдинова; пер. с тат.– осман. и примеч. А. Г. Хайрутдинова.– Серия «Исламская мысль в России: возрождение и переосмысление».– М.: ИД «Медина», 2022.– 200 с.; 3) ИМР проекты кысаларында, А. Хәйретдинов тарафыннан татар теленә тәрҗемә ителеп, Д. В. Мөхетдинов редакциясендә «Медина» нәшрият йортында басмага әзерләнә.

[4] Китап ИМР проекты кысаларында рус теленә тәрҗемә ителеп, Д. В. Мөхетдинов редакциясендә «Медина» нәшрият йортында басмага әзерләнә.

**1914**

32. «Маъидә» (СПб)[1].
33. «Дәүләт думасында мәет якмак мәсьәләсе» (СПб)[2].
34. «Бөек мәүзугларда уфак фикерләр» (СПб)[3].

---

[1] Китап: 1) 2018 елда рус теленә тәрҗемә ителеп басылды: Бигеев М. Д. Трапеза. Ислам в современном мире. 2018; 14(4):131–148; 2019; 15(1):47–68; 2) 2018 елда татар теленә тәрҗемә ителеп басылды: Хәйретдинов, Айдар. Муса Бигиевнең Азык-төлектә хәлал вә хәрам мәсьәләләренә карашы.– Қазан: Қазан инновацион ун-ты, 2018.– 46 с.; 3) 2020 елда рус теленә тәрҗемә ителеп басылды: Бигиев М. Д. Мусульманская трапеза / пер. с татаро-османского яз. А. Г. Хайрутдинова, предисл. А. В. Тимирясовой, Е. Л. Яковлевой; предисл. А. Г. Хайрутдинова.– 2-е изд.– Казань: Изд-во «Познание» Казанского инновационного ун-та, 2020.– 66 с. (Серия «Сокровищница Татарстана»); 4) 2020 елда татар теленә тәрҗемә ителеп басылды: Бигиев М. Җ. Аш табыны / госманлы-татар теленнән тәрҗ. А. Г. Хәйретдинов; кереш сүз А. Г. Хәйретдинов; кереш сүз А. В. Тимирясова, Е. Л. Яковлева.– Казан: Казан инновацион ун-тының «Познание» нәшр., 2020.– 66 б. («Татарстан хәзинәсе» сериясе); 5) 2022 елда рус теленә тәрҗемә ителеп басылды: Бигиев, Муса. Трапеза / Централизованная религиозная организация Духовное упр-е мусульман РФ; Моск.ислам. ин-т; Санкт-Петербургский гос. ун-т; под общ. ред. Д. В. Мухетдинова; пер. с тат.– осман., вступ. слово и примеч. А. Г. Хайрутдинова.– Серия «Исламская мысль в России: возрождение и переосмысление».– М.: ИД «Медина», 2022.– 132 с.; 6) ИМР проекты кысаларында, А. Хәйретдинов тарафыннан татар теленә тәрҗемә ителеп, Д. В. Мөхетдинов редакциясендә «Медина» нәшрият йортында басмага әзерләнә.

[2] Китап: 1) 2022 елда рус теленә тәрҗемә итеп басылды: Бигиев, Муса. Проблема кремации, озвученная в Государственной думе / Централизованная религиозная организация Духовное упр-е мусульман РФ; Моск.ислам. ин-т; Санкт-Петербургский гос. ун-т; под общ. ред. Д. В. Мухетдинова; пер. с тат.– осман. и примеч. А. Г. Хайрутдинова.– Серия «Исламская мысль в России: возрождение и переосмысление».– М.: ИД «Медина», 2022.– 64 с. 2) ИМР проекты кысаларында, А. Хәйретдинов тарафыннан татар теленә тәрҗемә ителеп, Д. В. Мөхетдинов редакциясендә «Медина» нәшрият йортында басмага әзерләнә.

[3] Китап: 1) 2014 елда рус теленә тәрҗемә ителеп басылды: Биги-

35. «Мөляхазә» (Петроград)[1].

**1915**

36. «Исляхат әсасләре» (Петроград)[2].

37. «Фикъһу әл-Коръәни» (Петроград)[3].

**1916**

38. «Хокук әсасия (124 статья). 1906 сәнә април 23 дә тәсдыйк кыйлынмыш әсас канунлар» (Петроград)[4].

39. «Зәкят» (Петроград)[5].

**1917**

40. «Шәригать әсасләре» (Петроград)[6].

41. «1917 ел 1–11 майда Москва шәһәрендә гомум Русия мөселман съезды хакында кыскача мәгълүмат» (Казан).

---

ев, М. Д. Избранные труды / Муса Дңаруллах Бигиев; [сост. и пер. с османского яз., введ., сн. и коммент. А. Хайрутдинова].– Казань: Татар. кн. Изд-во, 2014. 398 с.; 2) ИМР проекты кысаларында, А. Хәйретдинов тарафыннан татар һәм рус телләренә тәрҗемә ителеп, Д. В. Мөхетдинов редакциясендә «Медина» нәшрият йортында басмага әзерләнә.

[1] Китап ИМР проекты кысаларында, А. Хәйретдинов тарафыннан рус теленә тәрҗемә ителеп, Д. В. Мөхетдинов редакциясендә «Медина» нәшрият йортында басмага әзерләнә.

[2] Китап ИМР проекты кысаларында рус теленә тәрҗемә ителеп Д. В. Мөхетдинов редакциясендә «Медина» нәшрият йортында басмага әзерләнә.

[3] Китап, ИМР проекты кысаларында рус теленә тәрҗемә ителеп, Д. В. Мөхетдинов редакциясендә «Медина» нәшрият йортында басмага әзерләнә.

[4] Китап, ИМР проекты кысаларында рус теленә тәрҗемә ителеп, Д. В. Мөхетдинов редакциясендә «Медина» нәшрият йортында басмага әзерләнә.

[5] Китап: 1) рус теленә тәрҗемә ителеп, 2013 елда басылды: Бигиев М. Закят / Под общ. ред. И. А. Зарипова.– Наб. Челны: «Духовно-деловой центр «Ислам нуры».– 2013.– 228 с.; 2) ИМР проекты кысаларында, Д. В. Мөхетдинов редакциясендә «Медина» нәшрият йортында басмага әзерләнә.

[6] Китап ИМР проекты кысаларында, А. Хәйретдинов тарафыннан татар һәм рус телләренә тәрҗемә ителеп, Д. В. Мөхетдинов редакциясендә «Медина» нәшрият йортында басмага әзерләнә.

**1918**

42. «Гаилә мәсьәләләре» (Петроград).

**1923**

43. «Ислам милләтләренә дини, әдәби, иҗтимагый, сәйәси мәсьәләләр тәдбирләр хакъкында» (Берлин)[1].

**1927**

44. «Шәригать исламийә назарында мөскират мәсьәләләре» (Истанбул)[2].

**1931**

45. «Төркия бөек милләт мәҗлесенә мөрәҗәгать» (Каһирә)[3].

---

[1] Китап: 1) рус теленә тәрҗемә ителеп, 2006 елда басылды: Бигиев М. Избранные труды: в 2 т. / Муса Бигиев; Сост. и пер. с остан. А. Хайрутдинова. Т. 2: Обращение к Великому Турецкому Национальному Собранию, Введение к трактату «Аль-Муафакат», Воззвание к мусульманским нациям, Женщина в свете священных аятов благородного Корана.– Казань: Татар. кн. изд-во, 2006.– 256 с.; 2) ИМР проекты кысаларында, А. Хәйретдинов тарафыннан рус теленә тәрҗемә ителеп, Д. В. Мөхетдинов редакциясендә «Медина» нәшрият йортында басмага әзерләнә.

[2] Китап: 1) рус теленә тәрҗемә ителеп, 2022 елда басылды: Бигиев, Муса. Мускират: проблема опьяняющих напитков с точки зрения исламского шариата / Централизованная религиозная организация Духовное упр-е мусульман РФ; Моск.ислам. ин-т; Санкт-Петербургский гос. ун-т; под общ. ред. Д. В. Мухетдинова; пер. с тат.– осман. и примеч. А. Г. Хайрутдинова.– Серия «Исламская мысль в России: возрождение и переосмысление».– М.: ИД «Медина», 2022.– 160 с.; 2) ИМР проекты кысаларында, А. Хәйретдинов тарафыннан татар теленә тәрҗемә ителеп, Д. В. Мөхетдинов редакциясендә «Медина» нәшрият йортында басмага әзерләнә.

[3] Документ: 1) 2000 елда басылды: Хайрутдинов А. Г. Наследие Муса Джаруллаха Бигиева. Сборник документов и материалов. Ч.I.– Казань: Иман, 2000. С. 21–39; 2) 2006 елда басылды: Бигиев М. Избранные труды: в 2 т. / Муса Бигиев; Сост. и пер. с остан. А. Хайрутдинова. Т. 2: Обращение к Великому Турецкому Национальному Собранию, Введение к трактату «Аль-Муафакат», Воззвание к мусульманским нациям, Женщина в свете священных аятов благородного Корана.– Казань: Татар. кн. Изд-во, 2006.– 256 с.; 2) ИМР проекты кысаларында, А. Хәйретдинов тарафыннан әзерләнеп, Д. В. Мөхетдинов редакциясендә «Медина» нәшрият йортын-

## 1933

46. «Тарихның онытылмыш сәхифәләре» (Берлин)[1].
47. «Коръән кәрим айәт кәримәләренең могъҗиз гыйбарәләренә күрә, Йаҗүҗ» (Берлин)[2].
48. «Коръән кәрим айәт кәримәләренең могъҗиз ифадәләрендә, сәмиларның әнбияләре, сәмави китаблары» (Берлин).
49. «Коръән кәрим айәт кәримәләренең нурлары хозурында хатын» (Берлин)[3].

## 1935

50. «Әл-вәшигату фи накъди гакаъиди әш-шигати» (Каһирә)[4].
51. «Низаму әт-тәкъвими фи әл-ислами» (Каһирә)[5].
52. «Низаму ән-нәсьйи гыйндә әл-гарәби кабләл әл-ислами» (Каһирә)[6].
53. «Таъриху әт-тәшригы әл-исламийи» (Каһирә)[7].

---

да басылачак.

[1] Китап ИМР проекты кысаларында, А. Хәйретдинов тарафыннан татар һәм рус телләренә тәрҗемә ителеп, Д. В. Мөхетдинов редакциясендә «Медина» нәшрият йортында басмага әзерләнә.

[2] Китап ИМР проекты кысаларында, А. Хәйретдинов тарафыннан татар һәм рус телләренә тәрҗемә ителеп, Д. В. Мөхетдинов редакциясендә «Медина» нәшрият йортында басмага әзерләнә.

[3] Китап: 1) 2006 елда рус теленә тәрҗемә ителеп басылды: Бигиев М. Избранные труды: в 2 т. / Муса Бигиев; Сост. и пер. с остан. А. Хайрутдинова. Т. 2: Обращение к Великому Турецкому Национальному Собранию, Введение к трактату «Аль-Муафакат», Воззвание к мусульманским нациям, Женщина в свете священных аятов благородного Корана.– Казань: Татар. кн. изд-во, 2006.– 256 с.; 2) Китап ИМР проекты кысаларында, А. Хәйретдинов тарафыннан татар һәм рус телләренә тәрҗемә ителеп, Д. В. Мөхетдинов редакциясендә «Медина» нәшрият йортында басмага әзерләнә.

[4] Китап: 1) рус теленә тәрҗемә ителеп, 2002 елда басылды: Джарулла М. Критика шиитских воззрений. Аль-вашиа фи накд акаид аш-шиа. Челнок для раскрутки пряжи воззрений шиа. Казань: Изд-во «Иман», 2002. / Перевод с араб.– Шагавиев С. А.; 2) ИМР проекты кысаларында рус теленә тәрҗемә ителеп, Д. В. Мөхетдинов редакциясендә «Медина» нәшрият йортында басмага әзерләнә.

[5] Китап ИМР проектына кертелгән.

[6] Китап ИМР проектына кертелгән.

[7] Китап ИМР проектына кертелгән.

54. «Әййаму хәйати ән-нәбийй әл-кәрими» (Каһирә)[1].
55. «Ли-ма игътабара әш-шәргу әр-руъйата» (Каһирә).
56. «Китабу әл-хуҗҗати» (Каһирә).
57. «Усулу әл-фикъһи вә мәнабигу-һу» (Каһирә).
58. «Мәсахифу әл-әмсари» (Каһирә).
59. «Низаму әл-җамигыйати әл-исламийати» (Каһирә)[2].
60. «Тәфсиру әл-хуруфи әл-мукаттагати» (Каһирә).

**1944**

61. «Сахифату әл-фәраъиди» (Бһопал)[3].
62. «Сарфу әл-Куръәни әл-кәрими» (Бһопал)[4].
63. «Китабу тәртиби әс-сүвари әл-кәримәти вә тәнасүбүһу фи ән-нүзүли вә фи әл-мәсахифи» (Бһопал).
64. «Илһаму әр-рахмани фи тәфсири әл-Куръәни галә усули әл-имами Шаһ Вәлиуллаһ әд-Дәһләви мин ифадати әл-имами әс-Синди Губәйдуллаһ ибни әл-Ислами әл-ләти тәләкъкаһа минһу Муса Җаруллаһ» (Карачи).
65. «Хуруфу әваъили әс-сүвари» (Бһопал)[5].
66. «Тәъмину әл-хәйати вә әл-әмлаки» (Бһопал)[6].

**1945**

67. «Китабу әс-сүннәти» (Бһопал)[7].

**1946**

68. «Низаму әл-хилафәти әл-исламийәти әр-рашидәти әл-йәүмә фи гусури әт-тәмәддүни» (Бһопал)[8].
69. «Әл-Банку фи әл-ислами» (Бһопал)[9].
70. «Әл-Канунү әл-мәдәнийу фи әл-ислами» (Бһопал)[10].

[1] Китап ИМР проектына кертелгән.
[2] Китап ИМР проектына кертелгән.
[3] Китап ИМР проектына кертелгән.
[4] Китап ИМР проектына кертелгән.
[5] Китап ИМР проектына кертелгән.
[6] Китап ИМР проектына кертелгән.
[7] Китап ИМР проектына кертелгән.
[8] Китап ИМР проектына кертелгән.
[9] Китап ИМР проектына кертелгән.
[10] Китап ИМР проектына кертелгән.

# III бүлек.
# Муса әфәндenен китапларыннан өзекләр, кайбер хезмәтләре, документлар һәм хатлар

# Тарихи мәҗлес[1]

Вабур[2] Макарьядән бер чакрым кадәр кидәр китмәз, беренче класс салонында Владикафказ имамы мәшһүр шагыйрь Садыйк әфәнде Рәхимкол җәнаблары мәҗлес(к)ә мөнасиб бер гашер-е Коръән кәрим(н)е[3] гаять мөәссир[4] бер мәкам илә укуды.

Соңра һәммә халык вабурның өст катына чыкды. Саф саф утурмак ичүн йирләр хазирләнмеш иде. У сәгать Ока нәһере[5] үзәрендә[6], беренче дәфга[7], сөнни, шигый мөэмин карендәшләр, бере беренә йөрәкләрене ачуб, исламият инсаният намларына[8] карендәшлекләрене изһар итмәк[9] шадлыкларына наъил улды[10].

Газиз карендәшләр саф саф карар итделәр[11], «Тәрҗеман» шәрәфе ичүн Исмәгыйль бәк җәнабларыны тарихи мәҗлесдә рәъис итделәр.

Рәъис әфәнде мөҗәз[12] бер нотык сөйләде, җәмәгат(н)е хазирләде, мәҗлес ачды. «Ибтидаъ», «Хәйат-ы Каспий» җәридәләренең сахиб-е имтийазы[13] Гали Мәрдан бәк Тупчибаш

---

[1] Чыганак: Исляхат әсасләре. Төз. Муса Җаруллаһ. Петроград: Тип. М-А. Максутова, 1915. Б. 169–175. (Язма хәзерге татар теленә хәрефләтә күчерелеп, тәрҗемә ителмичә бирелә).

[2] вабур – пароход.

[3] гашер-е Коръән кәрим – Коръән кәримнең бер өлеше.

[4] мөъәссир – тәэсир итүче; нәтиҗәле.

[5] нәһер – елга.

[6] үзәрендә – өстендә.

[7] дәфга – тапкыр, мәртәбә.

[8] намларына – исемнәренә, хакларына.

[9] изһар итмәк – күрсәтү, белдерү.

[10] наъил улды – иреште, ия булды.

[11] карар итделәр – урнаштылар; утырыштылар.

[12] мөҗәз – кыска.

[13] сахиб-е имтийазы – дәүләт тарафыннан бирелгән рөхсәт иясе.

җәнаблары гаять мөъәссир гаять рухлы узун бер хөтбә сөйләде. Мәфһүме[1] шу иде:

«Әй мөэминләр, әй карендәшләр, бән бүген укадәр мәмнүн улдым[2] ки, шу мәмнүниятеми сез(г)ә һичбер лисанлә[3] тәгърифидәмәм[4], бән шу көн(н)е һичбервакыт хатырымдан чыкармам. Шу көн[5] бундан соңра гомум Русия мөселманлары ичүн һәр сәнә милли байрам көне улачагы шөбһәсездер».

«Без – төрек балалары; асылымыз бер, нәселемез бер, динемез бердер. Мәгърибдән Мәшрикълара кадәр бәзем бабаларымызның милке иде. Бабаларымыз укадәр каһарман бер милләт улдыклары хәлдә, шу көн Кафкасия тагларында Кырымның багларында Казанның кырларында, ата бабаларымызның милке улан үз ватанымызда үз тупрагымызда, үз ихтийаҗларымыз(н)ы данишмага[6] ихтийарымыз калмады. Шөкерләр улсун Ходайа… шу кадәр мәкерләренә гаддарларына[7] бакмайуб, сулар үзәрендә йөрәкләремези ачуб, бер беремези ру бе ру[8] күрүб, кучаклашуб, сәвешмийә бүгүн моваффак[9] улдык. Инде бән катган әминем[10]: бундан соңра әгәр без(г)ә сулар үзәрендә данышмага вакыт вирмәзләр исә, күкләрә чыкарыз, йолдызлар үзәрендә йир булурыз да, кинә[11] шу көнге байрами иҗра идәрез[12]».

Гали Мәрдан бәкнең шу тарихи хотбәсе гаять мөъәссир иде. Җәмәгатьнең эксәре аглады. Хөтбә узун иде, мәҗлесдә

---

[1] мәфһүме – аңлашылганы.

[2] мәмнүн улдым – шат булдым; шатландым.

[3] лисанлә – тел белән.

[4] тәгъриф идәмәм – аңлата алмыйм, белдерә алмыйм.

[5] шу көн – бу көн.

[6] данишмага – танышырга; белешергә.

[7] гаддарларына – хыянәтләренә.

[8] ру бе ру – кара-каршы; йөзгә йөз.

[9] муаффәкъ – ирешү, ия булу.

[10] катган әминем – катгый төстә инанам; һичшиксез ышанам.

[11] кинә – үч итеп.

[12] иҗра идәрез – үткәрәбез.

кятибләр фәланләр йук иде. Холасасы[1] улмак үзрә[2] хатырларда шу кадәр калмыш. Гали Мәрдан бәк хөтбәсе соңында, Әбу әс-Согуд әфәнде Әхтәм, Исмәгыйль бәк, йәнә берничә адәм нотык сөйләде. Вакытында йазылмамыш улмак бәласейлә хатырлардан чыкды.

Тарихи шу мәҗлесдә йалңыз иң мөһим мәсьәләләр сөйләнүб, һәр сүз әдәб даъирәсендә мәхәббәт әсасендә[3] иде. Шу мәҗлесдә гомуми бер иттифак гакыд кыйлынуб[4], карарның холасасы куршун[5] каләм илә йазылды. Баку моваккыт мәркәз тәгайен кыйлынды. Русия мөселманлары 16 шогъбә[6] тәкъсим кыйлынуб, һәр шогъбә мәркәздән киләчәк тәгълимата муафыйк эш күрәҗәк улды. Нәшер-е мәгариф[7], тәэсис-е мәкятиб[8], ислях-ы мәдарис[9] кеби милләтнең иң бөек ихтийаҗларына даъир[10] мәшһүр «дүрт маддә»дән гыйбарәт карар кабул кыйлынды. Шу аз заман эчендә мәҗлес тарафындан кабул кыйлынмыш карар – Русия мөселманларының үз араларында «дини бер рабита[11]» – «сәяси бер куәт» тәдарек идүб[12], истикъбалемез(н)е[13] тәэмин итмәк иде. Мәктәб мәдрәсәләремези, рухани идарәләремези ислях мәсьәләләре у карар(г)а дахил иде[14]. Русия мөселманлары арасына нәшер-е мәгариф вәсиләләре[15] у карарда күстәрелмеш иде. Мәҗлеснең карары

[1] холасасы – кыскасы.
[2] улмак үзрә – буларак.
[3] әсасендә – нигезендә.
[4] гакыд кыйлынуб – килешенеп; карар кылынып; төзелеп.
[5] куршун – кургашын; металл.
[6] шогъбә – җирле төркемнәр.
[7] нәшер-е мәгариф – мәгариф тарату.
[8] тәэсис-е мәкятиб – мәктәпләр ачу.
[9] ислях-ы мәдарис – мәдрәсәләрне ислях кыйлу (реформалау).
[10] даъир – даирәсенә кергән; кагылышлы.
[11] рабита – бәйләнеш, багланыш.
[12] тәдарек идүб – әзерләп; тәгайен итеп.
[13] истикъбаль – киләчәк.
[14] дахил иде – керә иде.
[15] вәсилә – чара, юл; ысул.

әһле исламның ихтийаҗларына, заманның икътизаларына[1] һәрҗиһәтлә гаять муафикъ[2] улуб, «иттифак»ның иң мөһим, иң бәрәкәтле тарихи мәҗлесе иде. Вабурда хазир[3] халыкның һәммәсе бер җан, бер карендәш кеби улды. Әүвәлләрдә бере дигәренә сәлам вирмәйән шигый илә сөнни кучаклашды, бер софрадан[4] тәгам йийүб, бер кадәхдән[5] су эчде, гаять самими мәхәббәтлә сохбәт итде.

Тарихда беренче дәфга Русия мөселманларының шу бөек мәҗлесләре хатырасыйчүн, «15 август» йәүм мәсгудене[6] милли бәйрәм итмәк карары кабул кыйлынуб, һәр сәнә 15 августда Макарья базарында гомуми бер нәдвә[7] дәгъвәт кыйлыначагы мәҗлеснең иттифакыйлә[8] кабул кыйлынды.

Шу тарихи иҗтимагымыз[9] ибтидасындан[10] ниһаясенә кадәр әдәб даъирәсендә дәвам итде; Ока нәһре үзәрендә тарихи хәрәкәт тәмам 13 сәгать имтидад итде[11]. Шу 13 сәгать «Иттифак» мөъәссисләре[12] ичүн иң кыйммәтле сәгать иде. Һәр адәмнең йөзендә у вакыт бөек бер шадлык әсәре вар иде. Һәркәс һәм хәл-е лисаныйлә[13] һәм кал-е лисаныйлә[14] мәҗлесдән, мәҗлеснең карарындан мәмнүниятләрене сөйләде.

Мәҗлесдә мөзакәрә-мөшавәрә[15] тәмам улды, карарлары куршун каләмлә йазылмыш иде; төн сәгать унберә кариб[16]

---

[1] икътиза – объектив таләп; объектив хаҗәт.
[2] муафикъ – туры килгән, яраклы.
[3] хазир – булган.
[4] софра – табын.
[5] кадәх – тустыган (ыстакан).
[6] йәүм мәсгуд – бәхетле ителгән көн.
[7] нәдвә – җыен, җыелыш, корылтай.
[8] иттифакыйлә – гомуми килешүе белән; бер тавыштан.
[9] иҗтимаг – җыелу, җыелыш.
[10] ибтидасындан – башыннан.
[11] имтидад итде – дәвам итте.
[12] мөъәссисләр – нигез салучылар, оештыручылар.
[13] хәл лисаныйлә – шатлык теле белән.
[14] кал лисаныйлә – көр тавышлы теле белән.
[15] мөзакәрә-мөшавәрә – фикер алышу-киңәшләшү.
[16] кариб – якын.

вабурымыз Макарья искәләсенә[1] йанашмакда[2] иде, нагяһ[3] бердән берә һәркәсдә бер һәйаҗан[4] хасыйль улды.

Диделәр: «Инде без(н)е пулис истикъбаль идәрсә[5], хәлемез нә улур?» «Шу йазылмыш кягыдләри[6] карарлари гаһедләри нәрәдә мохафаза идәрез[7]?» – «Вабур пристанә йанашдыкдан соң, бези гаскәр ихата идүб, тәүкыйф идәрсә[8], нә кыйлурыз?»

Шу вәсвәсә шайтанияләр җәмәгатнең әксәренә истиляъ итде[9]. Хәтта Исмәгыйль бәк җәнаблары да «Быракың кягыдләри суйа, бән аламам!»[10] диде. Кягыдләри бере беренә вирделәр, ләкин һичбер адәм кабул кыйлмады. Гакыйбәт, кягыдләри Рәшид әфәнде алды, һәрнә улур исә, улур[11], кягыдләри һәрхәлдә мохафәза идәрем диде.

Вабурның хисабы да күрелмәмеш иде. Шәйхулла әфәндейлә Габделкәбир әфәнде хисаби күрүб, тәмам идәҗәк улды. Рәшид әфәнде вабур капитанына «Свисток вирмә, (дудук чалма), пристанә акрынлык илә йанаш!» әмерене вирде.

Сәгать тәмам унбер йарымда вабур мәнзилә[12] йанашды. Рәшид әфәнде у дакыйкада вабурдан чыкды, тугры арабачылар тарафына йөгерде. Рәхмәтулла әфәнде Йелкибаеф җәнаблары бер лихач араба хазирләмеш иде. Бәрабәр бинделәр дә хайванлари вар куәтләрейлә йөгертделәр. «Иттифак» каһарманлары пулис әлендән нәҗатларына[13] тәшәккер итделәр!

---

[1] искәлә – пристань.

[2] йанашмак – якынаерга.

[3] нәгяһ – көтелмәгәндә, кисәк кенә.

[4] һәйаҗан – борчылу, курку; дулкынлану.

[5] истикъбаль идәрсә – каршыласа.

[6] кягыд – кәгазь.

[7] мохафаза идәрез – саклыйбыз, яшерәбез.

[8] тәүкыйф идәрсә – кулга алса.

[9] истиляъ итде – яулап алды; басып алды.

[10] быракың кягыдләри суйа, бән аламам – кягазьләрне суга ат, мин ала алмыйм.

[11] һәрнә улур исә, улур – ни булса да, булыр.

[12] мәнзил – ярга чыга торган урын.

[13] нәҗат – котылу.

Пристаньдә пулис фәлан йук иде, хәтта мөселманларның вабурлә сәяхәтләрендән дә пулисның хәбәре йук иде. Уйлә исә дә, у көн Макарья базарында мөселманлар арасында һәрнәүгы кыйлә калә[1] улмыш, бәгъзылары[2] «У адәмләри хөкүмәт нәфи идәр[3]» димеш; бәгъзылары вабурда вармадыклары ичүн бере берене тәбрик итмеш.

Ләкин тарихи мәҗлесдә хазир улмак шәрәфенә наъил улмыш бәхетле мөселманлара хөкүмәт тарафындан һичбер шәй[4] улмады, улмак мөмкин дә дәгел иде. Буны күрүб, мәҗлесдән мәхрум калмыш адәмләр тәъәссеф итделәр[5]. Хәтта Галимҗан хәзрәт кеби бер мөдәррис: «Бән вабура өлгерә алмадым; йукса, уйлә мәҗлесә вармак әлбәттә лязем иде», диде.

Вабурда кидүб килмәк, йиймәк-эчмәк харажы[6] тәкърибан[7] йидейөз рубль улды. Йөз йекерме адәм вар иде. Адәм башына алты рубль кадәр исабәт итде[8]. Кафказ мөселманлары үз адәмләрене хисаб итделәр дә, хассәләренә[9] нәкадәр исабәт итмеш исә вирделәр. Бәземгиләр[10] йөз адәмдән тәхминән[11] йекерме адәм үзенең хассәсенә чыкмыш парайи[12] вирде. Хараҗның бәкыясе[13] Сибириялеләрнең кисәләренә[14] йөкләнде.

Сиксән адәм арасында йекерме кадәр таләбә[15] вар иде. Таләбә бер парә вирмәйәчәк. Исмәгыйль бәк Гаспринскиы милләт баласы улмак сыйфатыйлә бер парә вирмәйәҗәк, Әбу

[1] һәрнәүгы кыйлә калә – төрле имеш-мимешләр.
[2] бәгъзылары – кайберләре.
[3] нәфи идәр – сөргенгә җибәрәчәк.
[4] шәй – нәрсә, әйбер.
[5] тәъәссеф итделәр – кайгыга төштеләр, үкенделәр.
[6] хараҗ – чыгымнар; тотылган акча.
[7] тәкърибан – якынча.
[8] исабәт итде – туры килде.
[9] хассәләренә – аерым алганда үзләренә; хосусан үзләренә.
[10] бәземгиләр – безнекеләр.
[11] тәхминән – чама белән, якынча.
[12] пара – акча.
[13] бәкыясе – калганы.
[14] кисә – кисет, букча; кошелек.
[15] таләбә – шәкертләр, студентлар.

әс-Согуд Әхтәмеф милләт хадиме[1] улмак җиһәтейлә[2] бер парә вирмәйәҗәк, Рәшид әфәнде дә бабай улмак шәрәфейлә бер парә вирмәйәҗәк; йәнә берничә буйлә бөек адәмләр вар иде, һичбере парә вирмәйәчәк. «Ходай вирде инде» дийүб, әнваг-ы шәрабләри[3] эчүб дә бер тиен парә вирмәз адәмләр дә булыначак[4].

Шу хәлләрнең һәрбере бәзем татарларның табигатьләрене тәкъдир йулында[5] иң дөрест бер мизандыр[6]. Милләт «хадимләренең» хакыйкате шу мизанлә гаять ачык мәгълүм улур.

Гомуми бер мәҗлес, милли иң бөек бер шадлык, кач йөз сәнәдә бер дәфга килә биләҗәк бер хидмәт! Үзенә исабәт идәҗәк хассайи кодрәте вар исә вирмәк әлбәттә һәр адәмнең вазифасыдыр, буруҗыдыр.

Ләкин бездә уйлә дәгел. Бәзем милләт «хадимләре» нәкадәр бай улур исә дә, бер парә вирмәз. Һәр мәсъраф[7] һәрвакыт бай кесәләрендән улур, һәр заман агырлыгы бай тәхәммел идәр[8]. Дөрест, байлар, биш адәм, ун адәм бер дәфга, ике дәфга, өч дәфга агырлыгы тәхәммел идәр, соңра бизәр улур. Ба хосус[9] Макарья кеби һәр сәнә[10], мөмкин хәйләләрнең һәрберейлә парә тупланур бөек базарда.

Казан байлары һәрбер мәсьәләдә «баш» улмак арзусында исәләр дә, «гомуми эшләрдә парә мәсьәләсе» килдеме, бер парә вирмәз, мәйдандан качар, һәммә агырлык башка вилаять байларына калур.

«Иттифак» дәвам итмәйүб, хараб улмыш исә, бөек сәбәбләрнең бере әлбәттә шудыр.

---

[1] хадим – хезмәтче; абруйлы хезмәтче.

[2] улмак җиһәтейлә – булу ягыннан; булуы аркасында.

[3] әнваг-ы шәрабләри – эчемлекләрнең төрлесен.

[4] булыначак – табылачак.

[5] тәкъдир йулында – бәя бирү, билгеләү юлында.

[6] мизан – үлчәү.

[7] мәсъраф – матди (акчалата) чыгымнар.

[8] агырлыгы бай тәхәммел идәр – авырлыкны бай(лар) күтәрә.

[9] ба хосус – аеруча, хосусан.

[10] сәнә – ел.

Йөз биңләрә малик хәзрәтләр, Гали Мәрдан бәк Тупчыбашы кеби йөзбиңләрә малик юристлар, Исмәгыйль бәк кеби помещиклар, ресторанлар(г)а кабаклар(г)а миллионларыны тәләф итмеш[1] мирзалар, буйлә гомуми милли эшләрдә бер парә вирмәк шуйлә турсун, җәмгыятьләрә килмәк ичүн йул хараҗәтләрене[2] дә иттифак кассасындан таләб идәрләр. 1906 сәнә декабрьдә Москва җәмгыятенә килүб һичбер эш күрмәйенчә кайтулары ичүн, Исмәгыйль бәк, Җантурин, Апанайеф, Максудоф кеби әгъзаларның һәрбере иттифак кассасындан парә алды. Йалңыз Рәшид, йалңыз бән алмадык.

Август 16да иртә Макарья урамларында магазинларда бәзем татарлар агызында һәр нәүгы сүзләр, хәбәрләр, лафлар сөйләнде. Бәгъзылар: «Кызылбаш халкы[3] мөселман булган икән!» димеш. Бәгъзылар: «Кызылбаш таъифәсейлә[4] иттифак дөрест түгел!» димеш. Шу ике бер әкаллиятдән магадә[5], мөселманларның һәммәсе Русия мөселманларының иттифакларыны, шигыйларның, сөнниләрнең дустлыкларыны гаять бөек мәмнүниятлә тәлякъкый итделәр[6], вабур мәҗлесендән мәхрумлыкларына тәъәссеф итделәр.

Әүвәлләрдә Кафказ мөселманларыйлә татарлар бере беренә сәлам вирмәзләр иде. Август 16да мөселманларның шигыйлары да, сөнниләре дә бере беренә сәлам вирүр, бер йирә тупланув карендәшчә сохбәт идәр иде. Буны күрүб гади татарларның бере димеш: «Агайлар, бу иттифак инде бик йахшы булды, күбдән шулай тийүш иде. Ләкин мин аңламыйм, ничек булды икән: безме шигыйлар диненә күчдек, әллә шигыйлармы бәзем динемезни кабул итделәр? Ничек кенә булса да, йарый инде».

[1] тәләф итмеш – тузгыткан; әрәм иткән.
[2] йул харәҗәтләре – юл хакы; билет, торак-фәләннәрнең бәясе.
[3] Кызылбаш халкы – азәрбайҗаннар, ягъни шигыйлар.
[4] таъифә – төркем, группа.
[5] әкаллиятдән магадә – азчылыктан кала.
[6] тәлякъкый итделәр – каршыладылар; кабул иттеләр.

Иттифак хәбәре йалңыз Макарья базарына махсур калмайуб[1], мөселман шәһәрләренең һәр тарафына мәгълүм улды, һәр тарафдан тәбрик телеграмлары килде: Кафкасия шәйхелисламы, Закафкасия мөфтисе, хаҗи Зәйнелгабидин Тәкыеф, Зәйнулла хәзрәт кеби бөек зәватдан[2] тәбрик телеграмлары ирешде.

У көн акшам Кафкасия мөселманларының башы Гашурбәкыф җәнаблары Русия татарлары шәрәфенә Соловьев мөсафирханәсендә[3] бөек бер зыяфәт[4] вирде. Зыяфәт бер «карендәшлек» мәҗлесе иде. Гаять ләзиз[5] Иран пылавы, кәбаб, соңра чәй-каһвә вирелде. Мәҗлес ниһаясендә Исмәгыйль бәк җәнабларыйлә Рәшид әфәнде берлек, карендәшлек, дустлык хакында мөъәссир нотыклар сөйләделәр. Мәхәббәт мәҗлесе сәгать унберә кадәр дәвам итде.

Шу әснада[6] бәгъзы адәмләр туплануб, вабурда йазылмыш, хазирләнмеш карарлари ислях идүб, тәртиб идүб, таза кягыдлара күчерделәр. Акланмыш у карар түбәндә тәрҗемәсейлә бәрабәр нәкыль кыйлыначак[7].

Август 16да Кафказ мөселманлары шәрәфенә[8] Русия татарлары зыяфәт вирде. Йөз илле адәмнең уйлә тәгаме[9] хазирләнмеш иде. Миһманларның әксәре туплandыкдан соң пулис мәныг итмеш исә дә, Рәшид әфәнденең һиммәтейлә[10] йахуд хәйләсейлә зыяфәт гүзәл дәвам итде, тәмам улды.

Шу зыяфәтнең башка җиһәтләрене йазмак китабның максадындан тышдыр. Ләкин «бөекләр»нең куркаклыклары, Казан мөселманларының уфаклыклары[11] мәҗлесләрнең

[1] махсур калмайуб – чикләнеп калмыйча.

[2] зәват – затлар, шәхесләр.

[3] мөсафирханә – кунакханә.

[4] зыяфәт – тантаналы аш мәҗлесе; банкет.

[5] ләзиз – тәмле.

[6] шу әснада – шул арада; шул вакытта.

[7] нәкыль кыйлыначак – җиткереләчәк.

[8] шәрәфенә – мәртәбәсенә; хакына.

[9] тәгам – сыйлар; ашамлыклар.

[10] һиммәтейлә – тырышлыгы белән.

[11] уфаклык – ваклык; тар күңеллелек.

иҗтимагларның һәрберендә заһир улур иде. У сәнә Макарья базарында иҗтимагларның иң бөек сәмәрәсе улмак үзрә Дахили[1] Русия мөселманларының арасында һәрҗиһәтдән көлли[2] мөнәсәбәт хасыйль улды. Хәтта тиҗарәт[3] җиһәтейлә мөнәсәбәт артды. Бөек могътәбәр[4] таҗирләрдән[5] Тәкый Задә Сафаров җәнаблары диде: «Макарьяда кач[6] сәнәдер тиҗарәт идәрем. Татарлар һичбер вакыт бәзем мәгазалардан[7] мал алмаз иде. Шу сәнә татар карендәшләрә алты биң рубеллек мал сатдым».

Мәҗлесләрнең шу гүзәл сәмәрәләренә ишарә улмак үзрә, Макарья зыяфәтләрене дә бурада йаздым.

1905 август 15 карары.

---

[1] Дахили – Эчке (Россия).

[2] көлли – киң, тулы; һәрнәрсәне дә колачлаган.

[3] тиҗарәт – сәүдә; алыш-биреш.

[4] могътәбәр – абруйлы; ихтирамлы.

[5] таҗир – сәүдәгәр.

[6] кач – ничә.

[7] мәгаза (гарәпчә мәхазин (товар саклау урыны) сүзеннән) – кибет, магазин.

## «Әл-Мөвафәкать»нең нәшер ителүенә кагылышлы бер-ике сүз[1]

Ислам гыйлемнәре тарихына игътибар күзе белән битараф буларак караган кеше, әһле иҗтиһадның[2] иҗтиһадларына һәрникадәр канәгать булса да, дини әсәрләр язучыларның шәригать гыйлемнәрен кягазьдә теркәү өлкәсендә сайлаган ысулларына ризалык йөзе күрсәтә алмаячак.

Мин биредә гарәп теленә караган фәннәр турында, Коръән кәримгә кагылышлы гамәли гыйлемнәр турында сүз йөртмичә, тәфсир, хәдис, фикъһы[3], усуль[4] кебек исламиятнең бары тик шәргый гыйлемнәренә[5] кагылышлы фикеремне бер-ике җөмлә белән белдерәчәкмен:

Галәме исламияттә ислам голямәсенең[6] каләмләре белән язылган тәфсирләр гаять күп. Ләкин гомуми сурәттә ул тәфсирләрнең һәрбере тырышлыкларын бары тик йә гарап теленең үзенчәлекләре, йә айәтләрнең риваять ителү җиһәтләренә багышлап, «нәуг-ы бәшәрнең[7] мәдәни яшәеше өчен юлбашчы» сыйфатында күкләрдән иңгән Коръән кәримнең гыйльми

---

[1] Чыганак: Китабу әл-мөвафәкати ли-имами әл-хафизи әл-мөфассири әл-фәкыйһи әл-усулийи әш-шәйхи Аби Исхак Ибраһим ибни Муса әш-Шатыйби радыйа Аллаһу ганһу. Казан: Сабах көтепханәсе, 1909. Б. 2–15. (Документ хәзерге татар теленә тәрҗемә ителеп бирелә).

[2] әһле иҗтиһад – иҗтиһад иткән (ягъни диндә, дин гыйлемендә хөр акылларына һәм белемнәренә таянып эш иткән) дин галимнәре.

[3] фикъһы – ислам хокукы, ислам юриспруденциясе; хокукның методологик нигезләрен, ислам дине чыганакларына таянып, шәригать хөкемнәрен булдыру алымнарын үз эченә алган дини гыйлем.

[4] усуль – биредә дин нигезләре (ысул-е дин) күздә тотыла.

[5] шәргый гыйлем – шәригатькә кагылышлы белем.

[6] голямә – дин галимнәре.

[7] нәүг-ы бәшәр – кеше заты; кешеләр.

һәм дөньяви җиһәтләрен ачыклауга тырышлык сарыф иткән һичбер тәфсир юк. Табари[1], Кәшшаф[2], Бәйзави[3] кебек галәме исламияттә иң абруйлы, иң хөрмәтле, иң гыйльми тәфсирләрнең эчтәлеге минем бу дәгъвамны исбат итә ала.

Мин бу сүземне мөфәссирләргә[4] тел тидерү өчен түгел, (مَّا فَرَّطْنَا فِي الكِتَابِ مِن شَيْءٍ) кебек сыйфатлар белән сыйфатланган Коръән кәримнең киңлегенә зыян китертмәү өчен һәрвакыт яңгыратып торам. Бу дәгъвамны исбат итү өчен дә, табигать галәме турында хикәят иткән, ләкин әле һаман да аңлатылмаган йөзләрчә айәтләрне шаһит кебек күрсәтә алам. Табигать турында сүз йөрткән айәтләрне искә алырга хаҗәт тә юк, чөнки, фикъһы хөкемнәренә караган айәтләрнең дә күпчелеге тәфсирләрнең һичберендә тиешле сурәттә ахырына кадәр җиренә җиткерелеп хәл ителмәгән рәвештә кала бирә.

Үзләренең гарәбилекләре[5] ягыннан, һәм дә мәгънәләренең аңлаешлылыгы ягыннан ап-ачык дәрәҗәсендә булган айәтләрнең тәфсирләрендә нигезсез каршылыклар булуы минем бу сүземә бер шаһит була түгелме?

[1] Табари (Әбү Җәгъфәр Мөхәммәд ибне Җарир әт-Табари, 839–923) – күренекле мөфәссир, Коръән тәфсире авторы, дин галиме, бүгенге көнгә кадәр сакланмаган җәгъфәри фикъһы мәзһәбенә нигез салучы фәкыйһ, дөнья яратылышыннан бирле IX гасырга кадәр кичкән тарихны үз эченә алган күләмле «Тарих әл-бүлдән вә әлмөлүк» исемле хезмәт язган мәшһүр тарихчы галим. 1980–2000 елларда әлеге хезмәт инглиз теленә тәрҗемә ителеп, 40 томда АКШта басылып чыга.

[2] Кәшшаф – Әбү әл-Касим Мәмүд бине Гомәр бине Мөхәммәд әл-Хуваризми әз-Зәмәхшәри (милади 1144тә вафат) тарафыннан язылган «әл-Кәшшаф ган хакаикъ гавамиз әт-тәнзил вә гойүн әлакавил фи вөҗүһ әт-тәэвил» исемле Коръән тәфсире.

[3] Бәйзави (Насыйретдин Әбү Сәгыйд Габдуллаһх ибне Гомәр әл-Байзави; милади 1286да вафат) – күренекле дин галиме, фәкыйһ, кәламчы фәйләсүф, тарихчы, «Тәфсир әл-Бәйзави» исемле Коръән тәфсире авторы.

[4] мөфәссир – Коръәнне тәфсир итү (эчтәлеген аңлату, ачыклау) белән шөгыльләнүче дин галиме.

[5] гарәбилек – Коръәннең гарәп телендә иңүенә һәм гарәп халык мәдәниятенә, яшәү рәвешенә бәйле булган үзенчәлекләре.

Риба[1] кебек икътисади мәсьәләләргә, шура[2] һәм идарә кебек сәяси мәсьәләләргә, хәмерне хәрам кыйлу кебек кеше тормышына, аның бәхет-сәгадәтенә һәр яктан бәйләнешле булган мәсьәләләрдә, никях-талак кебек гаилә мәсьәләләренә кагылышлы айәтләрнең тәфсирләрендә әһле тәфсирнең югары дәрәҗәдәге җитешсезлекләре минем бу дәгъвәмә катгый бер дәлил була алмыймы?

Игътикад[3] мәсьәләләрендә дәлил булырлык айәтләргә әһле кәлямнең[4] әдәпсез рәвештә һөҗүмнәре болай була: күбесенчә бер айәт белән ике капма-каршы дәгъване дәлилләүләре, «булырлык нәрсәме?» кебек бер тиенлек әһәмияте булмаган мәсьәләләрне дәлилләүгә соң дәрәҗәдә аяусыз кыяфәттә ярсый-ярсый ташланулары. Боларны белә торып, әһле кәлямнең, «барлыкның максаты нидер?» кебек иң олы мәсьәләләргә дәлил була алырлык айәтләр хакында вәкарьле кыяфәт китереп дәшми калулары минем бу дәгъвәмне раслый түгелме?

Һичбер адәмгә орыну нияте белән түгел, бары тик хакыйкатьне табу өмете белән, инде фикер йөртеп карыйк: безнең тәфсирләребез нидән шушындый булып калды?

Тәфсирдән кала, галәме исламияттә иң хөрмәтле, иң әһәмиятле гыйлем «гыйлем-е хәдис»тер. Чөнки «гыйлем-е хәдис» бер яктан безгә Коръән кәримне бәян итә, икенче яктан, сүзләре, эшләре, хөкемнәре белән хәятнең төзеклелегенә, бәхет-сәгадәтенә кешеләрне юнәлтү өчен җибәрелгән Рәсүл кәримнең һәрбер сүзен, һәммә эшләрен, бөтен хөкемнәрен безгә җиткереп тапшыра.

---

[1] риба – әҗәткә бирелгән акчаны арттырып кире кайтару; банк проценты.

[2] шура – киңәшләшү.

[3] игътикад (шулай ук гакыйдә) – ышану, яки ышанылырга тиешле нәрсәләр; игътикад турында кешеләр яза, әмма иман дигән нәрсәне Аллаһ үзе бирә: (أُوْلَئِكَ كَتَبَ فِي قُلُوبِهِمُ الْإِيمَانَ وَأَيَّدَهُم بِرُوحٍ مِّنْهُ) ягъни «Андыйларның йөрәкләрендә иманны язып куйды һәм аларны Үзеннән булган рух белән куәтләндерде» (58:22), шуңа күрә бу ике төшенчә арасында тигезлек билгесе куярга ярамый.

[4] әһле кәлям – кәлям гыйлеме белән шөгыльләнүчеләр.

Шундый иң әһәмиятле бер гыйлемдә ислам голямәсе нинди хезмәт кыйлган? Хакыйкатьне эзләп табу максаты белән бу мәсьәләгә дә битараф бер караш белән күз салыйк:

Шөбһә юк, ислам голямәсе хәдисләрнең иснадларына[1] кагылышлы нәрсәләрдә гаять зур хезмәт күрсәткәннәр. Ягъни хәбәр ителгән риваятьнең, ягъни хәдиснең тапшырылу рәвешләренә, равиларның, ягъни хәдисләрне хәбәр итүчеләрнең гаделлек, тәкъвалык кебек сыйфатларына кагылышлы нәрсәләргә карата үтә дә игътибарлы булып, соң дәрәҗә тырышлык белән, кимчелек вә җитешсезлеккә урын калдырмаслык кадәр җентекле сурәттә сүз йөрткәннәр.

Шөбһә юк, әһле хәдис, ягъни хәдис белгечләре хәдисләрне туплау эшендә кимчелекләргә урын калдырмаганнар. Ышанычлы хәдисләрне зәгыйфь я уйлап чыгарылган хәдисләрдән аралау хосусларында игътибарсызлык күрсәтмәгәннәр. Бу нокталардан караган кеше әһле хәдиснең гыйлем-е хәдистә күрсәткән хезмәтләре белән канәгатьләнә ала. Ләкин хәдисләрнең «кеше хәятендә әһәмияте, гыйльми мәсьәләләрдә файдасы» ноктасыннан караган кеше хәдис белгечләренең хезмәтләре белән әгәр канәгатьләнмәсә, хакы бар. Чөнки хәдис китапларын баштан ахырына кадәр актарып, укып, ул хәдисләрнең аңлатмаларын, дәлилләрен әһәмият үлчәве белән үлчәгән адәм анда җиңел һәм әһәмиятсез нәрсәләрнең һәрберен табачак, ләкин беркадәр әһәмияте булган мәсьәләләр табылса да, андыйлар гаять аз табылыр. Ә инде, иҗтимагый тормыш мәсьәләләренә нигез була алырлык кадәр, яки гыйльми фикерләрнең тәрәккыятенә җитәкчелек идәр кадәр әһәмиятле булган һичбер мәсьәләләрне хәдис китапларының аңлатмаларында һич табып булмый. Әлбәттә, мин бу гомумилектән «كيف كان بدء الوحى»[2] кебек тәрҗемәләрне, «فضائل الاخلاق»[3] хәдисләрендә бәян ителгән нәрсәләрне искәрмә кыйлам.

---

[1] иснад – 1) хәдисне тапшыручылар чылбыры һәм, 2) аны барлау, торгызу һәм тикшерү белән шөгыльләнә торган гыйлем.

[2] Вәхинең башлануы ничек булды?

[3] Әхлак фазыйләтләре (игелекләре).

Соңрак дәвердә хәдис китапларын язучылар тагын да күбрәк тырышлык кыйлганнар. Мөмкин кадәр күбрәк «истинбат» итим[1] дигән хыял белән, ул дәвер язучылары иң мәгънәсез, иң буш нәрсәләрне дә пәйгамбәр хәдисләреннән чыгара торган булганнар. Хәдиснең әһәмиятле мәгънәләрен бәян иткәннән соң булса ярар да иде. Ләкин соңрак дәвердә иҗат иткән ул язучылар хәдиснең әһәмиятле мәгънәләре турында дәшмичә, җыен юк-бар мәсьәләләргә олы игътибар биреп, тырышлыкларын юкка сарыф итә торган булганнар.

Һичбер адәмгә кимчелек тагу нияте белән түгел, бәлки хәлнең сәбәпләрен ачыклау өмете белән инде фикер итеп карыйк: безнең хәдис китаплары нигә мондый булып калды?

Тәфсир вә хәдистән соң, шәригать гыйлемнәре арасында әһәмияте ягыннан өченче урында фикъһы гыйлеме тора. Фикъһы гыйлеме Коръән айәтләре һәм нәбәви хәдисләргә нисбәтән өченче булса да, кеше тормышына карата булган әһәмияте ягыннан беренче дәрәҗәдәдер. Чөнки:

Коръән кәрим әһле исламның дәгъвасенә һәм игътикадына күрә, бөтен кешеләр өчен кыяматкәчә калачак күктән иңгән изге китап булса да, әлбәттә, шөбһәсез, бу хакыйкать бары тик фикъһы гыйлеменең кямиллеге белән, ислам фикъһысының да кешеләр тормышының төзеклелегенә тулысынча туры килүе белән раслана ала. Ислам диненең тәгълиматы иң югары тәгълимат булмаса, һәм ислам фикъһысы кеше тормышы өчен иң мөкәммәл бер гадел канун булмаса, ул чакта безнең бу игътикадыбыз нигезсез бер имандыр, дәгъвабез дә коры лафдан гыйбарәт булып кала.

Ислам рисаләте, ягъни Коръән, нигездә, кабатланмас бер игъҗаздыр[2], ягъни могъҗиза. Ләкин игъҗаз, әлбәттә, Коръәннең бары тик төзелешенә генә кайтып калмый. Чын мәгънәдә игъҗаз Коръәннең мәганәсенә бәйле. Болай булгач, Коръән кәримнең югары тәгълиматы, ислам шәригатенең фикъһы

---

[1] «истинбат» итим – берәр хәл яки күренешне өйрәнеп хөкем чыгарыйм.

[2] игъҗаз – башка һичкем тарафыннан кабатлана алмый торган могъҗизавилек.

гыйлеме кеше тормышы өчен иң яраклы, иң мөкәммәл канун булырга тиеш. Шулай булмаса, Коръән кәримдә мәгънә ягыннан игъҗаз була алмый.

Ләкин безнең мәзһәб[1] китапларында теркәлгән һәм бәян ителгән фикъһы гыйлеме Коръән кәримнең игъҗазын күрсәтә алырлык дәрәҗәдә мөкәммәлме? Кыяматкәчә бөтен кешелек дөньясы өчен иң яраклы, иң туры килгән гадел канун була алырлык кадәр иркенме? Кеше хәятендә көн саен, һәр гасырда калкып торган кыенлыкларны хәл итү ысуллары, туып торган сорауларның җаваплары безнең мәзһәб китапларында табыла алалармы?

Исламияткә карата булган кямил мәхәббәтем һәм игътикадымның кушуы белән, бу сорауларның һәрберенә: «Юк! Алай түгел»,– дип җавап бирергә мәҗбүрмен. Мин бу җавапны фикъһы гыйлеменә тел тидерү максатыннан түгел, ислам шәригатенә карата булган яратуымның кушуы белән әйттем.

Безнең фикъһыга караган гыйлемнәребездә гыйбадәт өлеше беркадәр мөкәммәл һәм тәфсилле булса да, мөгамәлат, ягъни җәмгыятьтә кешеләрнең үзара мөнәсәбәтләренә караган өлеше, һәм дә гомуми хокуклар, шәхси хокуклар өлеше, моннан тыш, дәүләт белән идарә итү эшләренә кагылышлы нәрсәләр бүгенгә кадәр тәртипкә салынган фикъһы голүмнәребездә[2] шул ук дәрәҗәдә мөкәммәл дәрәҗәдә түгел. Ул гынамы соң? Бәлки фикъһы китапларының кайбер бүлекләрендә башкарылуы мөмкин булмаган, өстәвенә гаделлеккә каршы килгән нәрсәләр дә бар.

Ни өчен безнең фикъһы гыйлемнәребез мондый булды? Минем игътикадымча, әлбәттә, һәр мөэминнең дә игътикады шундыйдыр, ислам фикъһысы кеше тормышы өчен иң туры

[1] мәзһәб – бу төшенчәнең тар, әмма иң киң таралган мәгънәсе исламда шәригать кануннарын булдыруда һәм тормышка ашыруда кайбер үзенчәлекләргә һәм аермаларга ия булган хокукый фикер һәм гамәл итүнең юнәлешләрен белдерә. Мәсәлән, хәнәфи, шафигый, мәлики һәм хәнбәли фикъһы мәзһәбләре күздә тотыла. Бу төшенчә шулай ук төрле дини-фәлсәфи фикер агымнарына карата да кулланыла.

[2] голүм – гыйлем сүзенең күплек шәкеле.

килгән канун, һәм дә саф гаделлек нигезенә урнаштырылган иң мөкәммәл хокук булырга тиеш иде.

Ләкин нигә безнең фикъһы гыйлемнәребез андый булмады соң?

Берсе берсенә асылда да, тармакларда да бәйләнешле булган хәдис һәм фикъһы гыйлемнәренең бу хәлләре нидән килеп чыккан?

Шөбһә юк ки, бу җитешсезлекләр Коръән кәрим кебек, Сөннәт-и рәсүл кебек шәригатьнең нигезләрендә түгел. Алар бөтенләй тышкы нәрсәләрдер. Һәр мөэмин, әлбәттә, шулай булуына инана.

Алай икән, ул җитешсезлекләр нидә?

Минем фикеремчә, ул кимчелекләр шәригатьнең нигезе булган Коръән кәрим белән Сөннәт-е рәсүлгә һәм дә бу икедән алынган шәригатькә карашыбыздадыр. Башка бер гыйбарә белән әйтсәм, «усул-ы фикъһы»дадыр[1]:

Усуль китапларында теркәлгән «усул-ы фикъһы» шәригать дәлилләре турында сүз йөрткәндә, ул сүзне ике нигез өстенә кора: берсе Шаригъ[2] тарафыннан каралган йөкләмә, яки хитаб, вәгазь нигезе. Икенчесе – өммәт тарафыннан йөкләмәләрне җиренә җиткереп үтәү, ягъни буйсыну нигезе. Бу ике нигезне исәпкә алганда, усул-ы фикъһы ике өлештән тора: ул ике өлешнең берсе – дәлилләрдән, икенчесе – хөкемнәрдән гыйбарәт. Әүвәлге өлеш, язучыларның күбесенә хас булган гадәткә күрә, дүрт дәлил: Китап, Сөннәт, иҗмаг, кыйяс турында сүз йөртә. Китап турында сүз барганда, сүзнең асылы аның гарәбилегенә, ягъни – күренеш, дәлиллек, кулланылыш, аңлаешлылык яклары белән мәгънәне белдерүгә кайтып кала. Бу йөздән, сүз Китапның төзелеше вә эчтәлегенең дәлил булу куәте, мәгънәләрнең аңлаешлылыгына бәйле булган мәсьәләләрдән гыйбарәт булып кала. Сөннәт нәбәвия турында сүз йөртелгәндә, гомумән, китап язучыларның гадәтенә күрә, сөннәтнең гарәбилегенә бәйле булган мәсьәләләр

[1] ысул-е фикъһы – фикъһы гыйлеменең методологик нигезләре.

[2] Шаригъ – шәригать хөкемен булдырып аның үтәлешен йөкләүче, ягъни Аллаһ тәгалә һәм аның илчесе.

искә алынмый. Чөнки китап язылганда ук аннан әүвәл куелган һәм хәл ителгән мәсьәләләр белән канәгатьләнү хасыйль була. Биредә нигездә яткан сүз теге яки бу сөннәтнең сәнәде[1] белән чикләнелә. Әледән әле биредә булып алган бәхәсләр дә зикер кыйлына[2]. Ләкин, мәгълүмдер, моның белән сөннәтнең дәлил буларак кулланылыш даирәсе киңәйми.

Ниһаять, китап язучылар иҗмагъ[3] турында сүз йөртәләр. Анда иҗмагъның мәгънәсе, аның дәлил булу куәте, дәрәҗәләре зикер ителә. Чынлыкта, иҗмагъ гыйльми мәсьәләне хәл итү яки исбат итү өчен дәлил була алмый. Ул бер хөкемне, бер мәсьәләне гамәлгә ашыру өчен тик бер юл, бер чара гына булса да, әһле усуль[4] иҗмагны бер дәлил кебек, хәтта иң зур дәлил кебек кабул итәләр. Иҗмагъ дигән нәрсә канун барлыкка китерү, аны кабул итү, гамәлгә ашыру мәсьәләләрендә гаять олы әһәмияткә ия була алырлык иң зур таяныч була алса да, безнең әһле усуль иҗмагъның ул җиһәтенә бер тиенлек, яки тиешле кадәр әһәмият бирмәгән. Моның болай булуы аркасында кеше яшәешенең тәрәккъыятенә сәбәпче булырга тиешле ислам шәригатенең киңлегенә бик нык торгынлык, тоткарлау барлыкка килгән. Мең ел элек безнең фикъһы гыйлемнәребез нинди булсалар, бүген дә һаман шул дәрәҗәдә калганнар.

Иҗмагъдан соң усуль китапларында кыйас[5] турында сүз йөртелә. Китап, я Сөннәт, я иҗмагъ тарафыннан расланган бер хөкемне башка хәлләргә, ситуацияләргә туры китерү өчен, кыйаска караган бүлекләрдә аны куллану шартлары искә алына. Мәзһәбләрнең төрлелеге аркасында шартлар, һәм

[1] сәнәд – хәдисне тапшырган шәхесләр (равиләр) чылбыры.

[2] зикер кыйлына – искә алына.

[3] иҗмаг (гарәп.) – һәркайсы фәкыйһ тарафыннан бертавыштан яки фәкыйһләрнең күпчелеге тарафыннан кабул ителгән шәригать хөкеме.

[4] Әһле усуль – фикъһы гыйлеменең методологиясе (ысуллары) белән эш итүче шәригать белгечләре.

[5] кыйас – шәригать хөкемнәрен чыгарганда аннан алда булган охшаш хәлләр, хөкемнәр белән чагыштыру нигезендә карар кабул итү ысулы.

дә кыйасның дәлил булу куәтенә карашлар төрле була. Шаригъ тарафыннан хөкемнең гыйлләсе[1] искә алынмаган булса, ул чакта ике очракны үзара килештәрә торган гыйлләне таба алу бик авыр була. Ул хәтта табылса да, ул табылган нәрсәнең, әлбәттә, гыйлләә булуына дәлил таба алу шулай ук авыр була. Яки гыйлләә булуы ихтимал булган нәрсәләр күп булып, кыйас безгә чуарлыктан, каршылыклардан башка җимешләр бирә алмый. Бу йөздән, кыйасның дәлил була алуы белән ислам шәригате берникадәр киңлеккә ирешә алмый.

Һәрхәлдә, фикъһы усульләренең шәргый дәлилләргә карашы йә гарәбилек, йә риваять якларының чикләреннән чыгып китә алмый. Минем гөманымча, әһле иҗтиһадның иҗтиһады да, мөгаен, әлеге ике киртә белән чикләнелеп калган кебек күренә.

Шундый бер ысул өстенә тәфсир, хәдис, фикъһы кебек иң зур шәригать гыйлемнәре корылып, бу өч гыйлемнең югарыда бәян ителгән җитешсезлекләре, минем гөманымча, тик шушы нәрсәдән үсеп чыккан:

Коръән айәтләрен тәфсир иткәндә, мөфәссирләр, гомумән, бер юнәлешне сайлап, һәммә тәфсирләрен, һәммә дәлилләүләрен усулы фикъһы китапларында бәян ителгән ысулларга бина иткәннәр дә, Коръән кәримнең мәгънәләрен гарәбилек һәм риваять кебек ике какшамас чик белән чикләп, фикер һәм акыл белән табыла алган мәгънәләрне бөтенләй санга сукмаганнар. Кеше тормышында канун булачак шәригать хөкемнәренә дәлил булып торган айәтләрнең тәфсирдә бары тик гомуми һәм хосусый үзенчәлекләренә, гыйбарә төзелешенә, ишарәләргә, аларның мөхкәмлегенә[2], мөҗмәллек[3] кебек төзелеш кисәкләренә әһәмият биреп, ул хөкемнәрнең кеше тормышында әһәмиятенә, тәэсиренә улкадәр игътибар

---

[1] гыйлләә – теге яки бу шәригать хөкеменең нигезендә яткан башлангыч сәбәп, этәргеч, алшарт.

[2] мөхкәм – «Әл-Гыймран» сүрәсенең 7 нче айәтенә күрә, бу сүз теге яки бу айәтнең мәгънәсе ачык һәм аңлаешлы булуын белдерә торган төшенчә.

[3] мөҗмәл – аз сүзлек; аз сүз белән тирән мәгънә белдерү.

күзе белән карамаганнар. Бу хәл ислам шәригатенең торгынлыгына, ягъни тәрәкъкый итмичә бер хәлдә катып калуына иң куәтле бер сәбәп булган.

Әһле хәдис, әһле тәфсир кебек, истинбатларын[1], истидляльләрен[2] усуль китапларында бәян ителгән ысулларга нигезләп, хәдисләрнең гарәбилегеннән күбрәк аларның нигезендә яткан риваятьләргә игътибар биргәннәр дә, кешенең яшәеше өчен канун, гыйбадәте өчен юл булачак иң мөһим шәргый хөкемнәрдә бер хәдиснең төрле риваятьләрен нигез итеп алганнар. Бер тарафтан, биредә дәлил булмаган нәрсәләрне дәлил итү куркынычы, икенче тарафтан, канун кебек иң нигезле нәрсәләрне ихтиляф-е әлфазга[3] кайтарып калдыру кебек мөнәсәбәтсезлек тә бар. Вак нәрсәләрнең һәрберенә карата күпсанлы хәдисләр, хисапсыз риваятьләр искә алып, әһәмиятле нәрсәләрнең күбесенә карата бер генә хәдис булса да искә алмаганнар. Бу хәл, шөбһә юк, «шәргый дәлилләр»гә «тарыз-ы назар»дан[4] яки кеше тормышына әһәмият бирмәүдән килеп чыга.

Мөхәддисләр[5] хәдисләрне, мөфәссирләр аятьләрне бәян иткәндә әйткән сүзләрен һәрчак усуль китапларында искә алынган ысул өстенә бина кыйлып, Китап[6] һәм Сөннәтнең максатларына, канун булачак нәрсәләрнең кеше яшәешендә торкан әһәмиятләренә тиешле кадәр игътибар итмәгәннәр, чөнки тиешле дип тапкан ысулның даирәсе җитәрлек кадәр дәрәҗәдә киң түгел.

---

[1] истинбат – берәр мәсьәләне өйрәнеп, аңа карата шәригать хөкеме, яки карар чыгару.

[2] истидляль – дәлилләргә таянып нәтиҗә чыгару: нәтиҗәгә килү өчен дәлилләр китерү.

[3] ихтиляф-е әлфаз – әйтелеш төрлелеге, нинди дә булса сүз, риваять яки хәбәрнең төрле әйтелешләргә (артикуляциягә) ия булуы.

[4] тарыз-ы назар – нинди дә булса мәсьәләгә карау, аны бәяләү рәвеше яки шәкеле.

[5] мөхәддис – хәдисләр белгече, хәдис гыйлеме остасы.

[6] Китап – Коръән.

Голүм фикъһиябезгә[1] килгәндә: безнең фәкыйһләр[2] назымның[3] дәлиллегенә, ничек кенә булса да бер риваятьнең барлыгына иң зур әһәмият биреп, шәригать хөкемнәрен әлеге ике нигезгә бина итәләр. Бер риваять эзләнеп табылса, яки усуль китапларында бәян ителгән юлларның бере белән йә ясалмалылык, йә тәэвил[4] белән булса да, назымның дәлиллеге, гүя, исбат кыйлынса, шул чакта хөкемнәрнең башка нечкәлекләре турында сүз йөртмиләр. Кешеләрнең мәдәни хаҗәтләренә, әйтик, бер тиенлек тә әһәмият бирмиләр.

Риба, фаъиз[5] кебек әле һаман да хәл ителмәгән олы мәсьәләләр, мөтга[6] һәм тәхлил[7] кебек исламият йөзен мәңгебакый кызартачак шәргый хәйләләр кебек һәм исламиятне, һәм канунны иң ачык сурәттә мыскыл итә алачак нәрсәләр минем сүзләремне беркадәр раслый түгелме?

Барлы-юклы фаразларны соң дәрәҗә тырышлык белән таратып, һәйәт иҗтимагыя өчен беркадәр әһәмияте булган, яки иң олы әһәмияте булган мәсьәләләр турында сүз кузгатмаган, яки ул хакта әйтеп тә, хәл итә алмаган фикъһы китаплары гомумән минем бу сүзләремә шаһит була түгелме?

«Мәдәният юлына кердем инде», дип дәгъва кыйлган ислам дәүләтләреннән берсе генә булса да нигә шәригать исламия кануннары белән идарә ителми?

Гасырлар буенча Коръән айәтләрен, пәйгамбәр хәдисләрен укып, биш-ун томнан гыйбарәт булган фәтва китапларын күреп укып чыккан фәкыйһләр милләт һәм дәүләт идарәсе

[1] голүм фикъһия – ислам хокукы (аның ысуллары / методологиясе һәм гамәли алымнары) белән эш итүче дини гыйлем.

[2] фәкыйһ – ислам хокукы (аның ысуллары / методологиясе һәм гамәли алымнары) белгече.

[3] назым – төзелеш, тәртип, структура (Коръән текстына карата кулланыла торган төшенчә).

[4] тәэвил – Коръән айәтләренең (яки хәдисләрнең) мәгънәләрен символик-аллегорик төстә аңлату.

[5] фаъиз – банкка саклауга тапшырылган акчадан алынган процент.

[6] мөтга – вакытлы никях.

[7] тәхлил – вакытлы никях коруның бер шәкеле.

өчен кирәкле булачак кануннарны, исляхәтне[1] нигә әзерли алмыйлар?

Шәригать исламияне арка атып та, Аурупа кануннарына мөкиббән китү кебек хурлыкны ислам хөкүмәтләре ничек кичерәләр? Үз телләре белән «тиешле дәрәҗәдә яраклы кануннар шәригать исламиядә юк!», дип әйткән булалар түгелме? Алайса безнең фикъһыга караган гыйлемнәребез нигә андый яраклы кануннарны безгә әзерләмәгән? Нигә әзерләми?

Гөман итәм ки, мондый сорауларның һәрбере минем ул дәгъваларымның дөреслеген исбат итә ала.

Мин ул дәгъваларымны ихлас бер ният белән, олы ышаныч белән яңгыратам. Ләкин, Ходай белеп тора: бу нәрсәләрне ислам голүмнәренә орыну хыялы белән түгел, бәлки шәригать исламиягә карата булган олы бер мәхәббәт белән, нигезле игътикад белән дәгъва итәм. Чөнки беләм: безнең Коръән кәрим һәм мөкатдәс, һәм могъҗизави бер Китап сәмавидер[2]. Аның игъҗазы[3] исә бары тик төзелеше белән түгел, шөбһә юк, мәгънәсе белән дә раслана. Алай икән, Коръән кәримнең игъҗазына туры килгән бер могъҗизави шәригать, ягъни галәме мәдәнияттә[4] тиңе табыла алмаган дәрәҗәдә иң мөкәммәл[5] бер шәригать, яки канун, әлбәттә, исламияттә булырга тиеш иде. Фәкать, иң мөкәммәл бер канун булу сыйфаты белән һәммә кеше тарафыннан бөтен галәме мәдәнияттә кабул ителә алырлык фикъһы голүмнәре нидән галәме исламияттә юк? Булуы, шөбһә юк, тиеш иде.

Шәригать голүмнәребезнең, аеруча фикъһы голүмнәребезнең ул кимчелекләре, минем гөманымча, безнең шәргый

---

[1] исляхәт – яхшырту; үзгәртеп кору; камилләштерү.

[2] Китап сәмави – Күктән иңгән китап.

[3] игъҗаз – Коръәннең могъҗизавилеге, һичкем тарафыннан кабатлана алмаган табигатькә ия булуы; Бигиев бу төшенчәне, гомумән, ислам диненә, шәригатькә карата да кулланган.

[4] галәме мәдәният – цивилизацияле рәвештә тормыш итүче кешелек дөньясы; Бигиев китапларында тәрәккыятьтә алга киткән Көнбатыш мәдәнияте мәгънәсендә килә.

[5] мөкәммәл – камиллекнең югары дәрәҗәсенә ия булган.

дәлилләргә һәм шәригать хөкемнәренә булган карашыбыздан, ягъни усул-ы фикъһыдан килеп чыга, чөнки галәме исламияттә таралыш тапкан усуль китаплары, гомумән, югарыда бәян ителгән өслүб нигезендә язылып, һичбере Китап һәм Сөннәтнең иң зур тәшригый[1] максатларын ни кыска сурәттә, ни тәфсилләп бәян итмәгән, шәригать белән хәят инсаниянең[2] үзара мөнәсәбәтләрен, кыска бер сүз белән булса да, күрсәтмәгән, хәят инсаниягә файда китерү турында, киң һәм тирән сурәттә түгел, хәтта кыска сурәттә дә сүз йөртмәгән. Бу сәбәп белән усул-ы фикъһының даирәсе гаять тар булган, голүм фикъһиябез мең ел элек нинди булса, шундый булып калган.

Голүм фикъһиябезне исламның югарылыгына туры килгән иң камил, иң киң сурәттә тәртипкә салып теркәүнең кирәклеге белән килешәбез икән, яки килешәчәк булсак, ул чакта безгә иң әүвәл ике нәрсә ляземдер[3]:

Беренчедән: башлары кирәкле голүмнәр, заманави фәннәр белән тулы булган ихлас хөр фәкыйһләр кирәк.

Икенчедән: Китап һәм Сөннәтнең тәшригый максатларын, хәят-е бәшәрнең[4] һәм зарури, һәм өстәмә хаҗәтләрен, хокукның чыганакларын, носусның[5] мәзһәб белән чикләнмәгән сурәттә шәригать хөкемнәренә дәлил булуларын, имам Әбү

---

[1] тәшригый – ислам диненең асыл чыганакларына (Коръән белән Сөннәткә) таянып шәригать кануннарын булдыруга караган.

[2] хәят инсания – кешенең яшәеше.

[3] лязем – кирәк, тиеш; кирәкле, тиешле.

[4] хәят-е бәшәр – кешенең яшәеше.

[5] носус – ислам диненең нигезен тәшкил иткән текстлар, ягъни Коръән айәтләре һәм хәдисләр.

Хәнифә[1], имам Малик[2], имам Шафигый[3], имам Әхмәд[4] кебек мөҗтәһидләрнең[5] ислам шәригате белән адәм баласының тормышына карашларын мөкәммәл сурәттә бәян итә торган бер «усул-ы фикъһы» кирәк.

Бу ике нәрсә, ягъни мәгълүматлы, ихлас, хөр фәкыйһләр белән дөрес мәганәдә «усул-ы фикъһы» бездә булса, шул чакта исламның игъҗазына туры килә торган бер могъҗизави шәригать, ягъни мәдәният галәмендә тиңе булмаган дәрәҗәдә иң мөкәммәл бер канун, шөбһәсез, бездә булыр иде. Шул чакта без Коръән кәримнең игъҗазын мәдәният галәмендә исбат итә алыр идек. Шул чакта исламияткә иманыбыз куркуга корылган иман түгел, басыйрәткә[6] корылган иман булыр иде.

Фанатиклык корбаны булган кеше инкяр итә алса да, ләкин гаделлек иясе булган кеше һичкайчан инкяр итә алмас: бүгенгә кадәр исламият галәмендә кабул ителеп килгән «Тәу-

---

[1] имам Әбү Хәнифә (Әбү Хәнифә ән-Ногман ибне Сабит әл-Күфи / имам Әгъзам; 699–767) – күренекле дин галиме, шәригать белгече, фәкыйһ, хәдисләр белгече, дүрт фикъһы мәзһәбенең берсенә, ягъни хәнәфи мәзһәбенә нигез салучы.

[2] имам Малик (Малик бине Әнәс бине Малик әл-Әсбахи әл-Мәдини, 713–795) – күренекле шәригать белгече-фәкыйһ, хәдис белгече-мөхәддис, фикъһыда мәлики мәзһәбенә нигез салучы, «әл-Мөваттәъ» дип аталган мәшһүр һәм абруйлы хәдисләр җыентыгын төзүче.

[3] имам Шафигый (Әбү Габдуллаһ Мөхәммәд ибне Идрис әш-Шафигый; 767–820) – күренекле фәкыйһ, хәдис белгече, шафигый фикъһы мәзһәбенә нигез салган галим.

[4] имам Әхмәд (Әбү Габдуллаһ Әхмәд ибне Мөхәммәд әш-Шәйбани / Әхмәд ибне Хәнбәл; 780–855) – күренекле фәкыйһ, мөхәддис, хәнбәли мәзһәбенә нигез салган галим.

[5] мөҗтәһид – иҗтиһад кыйлучы, ягъни фикъһы өлкәсенә караган мөһим мәсьәләләр буенча мөстәкыйль хөкемнәр, карарлар чыгару хокукына ия булган олы дин галиме, шәригать белгече.

[6] басыйрәт – чынбарлыкны аңлы һәм уяу хәлдә, аек акыл белән күрү һәм кабул итү.

зыйх»[1], «Усулү Баздави»[2], «Фосулү әл-бәдаигъ»[3], «әт-Тәхрир»[4], «Җәмгу әл-җәвамигъ»[5], «Әл-Мәхсуль»[6], «Минһаҗу әл-

---

[1] «Тәүзыйх» (التوضيح) – Хәлил бине Исхак әл-Җүндинең (шулай ук Синди Хәлил, (милади 1365тә вафат) исеме белән танылган) «Китабу әт-тәүзыйхи фи шәрхи әл-мохтасари әл-фәргы ли Ибни әл-Хаҗиби» исемле китабы күздә тотыла. Әлеге әсәр милади 12409да вафат булган Әбү Гамер Җәмалетдин Госман ибне Гомәр ибне Әбү Бәкер ибне Йунысның (шулай ук: Ибне әл-Хаҗиб) «Җәмгу әл-өммәһат» исемле китабына караган киңәйтелгән аңлатма (шәрех) буларак язылган.

[2] «Усулү Баздави» (اصول البزدوى) – китапның тулы исеме «Кәнзү әл-восули илә мәъфати әл-усули». Әлеге әсәр, милади 1089да вафат булган Әбү әл-Хәсән Әбү әл-Гусыр Фәхрелислам Гали бине Мөхәммәд бинә әл-Хөсәен бине Габделкәрим әл-Паздави тарафыннан язылып, хәнәфи мәзһәбе буенча асыл хезмәтләрнең берсе булып санала.

[3] «Фусулү әл-бәдаигъ» (فصول البدائع) – китапның тулы исеме «Фосуль әл-бәдаигъ фи усуль әш-шәраигъ». Фикъһы методологиясенә багышланган бу хезмәтне милади 1431дә вафат булган Мөхәммәд бине Хәмзә бине Мөхәммәд әл-Фәннари (шулай ук: Шәмсетдин әл-Фәннари) исемле фәкыйһ язган.

[4] «әт-Тәхрир» (التحرير) – китапның тулы исеме «әт-Тәхрир фи гыйлемел-усуль» Милади 1457дә вафат булган Кәмалетдин Мухәммәд бине Габделвахид бине Габделхәмид әс-Сиваси әл-Искәндәри (шулай ук: Ибн әл-Хумам) исемле шәригать белгеченең фәкыйһләр белән кәламчеләрнең ысулларын үз эчендә берләштергән хезмәте.

[5] «Җәмгу әл-җәвамигъ» (جمع الجوامع) – милади 1370тә вафат булган Таҗетдин әс-Сөбыкыйнең фикъһы методологиясенә багышланган китабы.

[6] «әл-Мәхсулү» (المحصول) – китапның тулы исеме «әл-Мәхсулү фи гыйльми усули әл-фикъһи». Әсәр әшгари кәлам мәзһәбенең күренекле вәкиле булган дин галиме, мөфәссир Фәхретдин әр-Рази (милади 1210да вафат) тарафыннан язылып, фикъһы методологиясенә багышланган.

восуль»[1], «Әл-Мөнтәһа»[2], «Тәнкыйх»[3], «Мөсәлләм әс-сөбүт»[4] кебек усуль китаплары югарыда бәян ителгән теләкләребезнең меңнән берен дә үти алырлык дәрәҗәдә түгел. Әлбәттә, бары тик әбхас ляфзыя[5] белән ихиляфәт кәлямиядән[6] гыйбарәт булган китаплар дөрес мәгънәдә усуль була алмыйлар.

Иң дөрес мәганәдә «усул-ы фикъһы» була алырлык бер китап әдәбият исламия арасында бар исә, ул да булса, тик бер «Әл-Мөвафәкать»тер.

«Әл-Мөвафәкать» Китап һәм Сөннәтнең тәшригый максатларын иң киң сурәттә бәян итә. Кешенең зарури һәм өстәмә хаҗәтләренә иң дикъкатьле сурәттә карый. Шәргый дәлилләр белән хәят-е инсанның[7] бәйләнешләрен иң төпле шәкелдә ачыклый. Һәрбер мәсьәлә турында гаять хөр сурәттә хөкем йөртеп, укучыларга бары тик акыл даирәсе белән чикләнелгән иң хөр бер караш тәкъдим итә.

---

[1] «Минһаҗу әл-восуль» (منهاج الوصول) – китапның тулы исеме «Минһаҗу әл-восули илә гыйлмьи әл-усули». Фикъһы методологиясенә багышланган әлеге хезмәтне казый Насыйретдин Әбү Сәгыйд Габдуллаһ бине Гомәр бине Мөхәммәд әл-Бәйзави (милади 1286да вафат) язган.

[2] «әл-Мөнтәһа» (المنتهى) – хәнбәли мәзһәбендә кабул ителгән фикъһы методологиясенә багышланган әлеге хезмәтне Ибнеән-Нәҗҗар исеме белән танылган Такыйетдин Мөхәммәд бине Әхмәд әл-Фөтухи әл-Хәнбәли (милади 1564тә вафат) язган.

[3] «Тәнкыйх» (تنقيح) – бу исем ике китапка карый ала: 1) Шиһабетдин әл-Карафинең (мил. 1285тә вафат) «Тәнкыйху әл-фосули»енә, яки 2) милади 1346да вафат булган «Садрышшәригать әс-Сани Гобәйдуллаһ бине Мәсгуд бине Таҗҗешшәригать Гомәр бине Садрышшәригать әл-Әүвәл Гобәйдуллаһ бине Мәхмүд әл-Мәхбүби әл-Бохариның «Тәнкыйху әл-усули»енә.

[4] «Мөсәлләмү әс-сөбүт» (مسلم الثبوت) – хәнәфи мәзһәбендә кабул ителгән фикъһы методологиясенә багышланган бу хезмәтне һиндыстанлы фәкыйһ Мөхиббеллаһ бине Габдешшөкүр әл-Һинди әл-Бихари (мил. 1707дә вафат) язган.

[5] әбхас ляфзыя – буш сүз, сафсата.

[6] ихиляфәт кәламия – кәлам гыйлеменең үзара каршылыклы карашлары.

[7] хәят-е инсан – кешенең яшәеше; кеше тормышы.

Безнең голүм фикъһиябез, тәфсир гыйлемебез белән хәдис гыйлемебез иң югары кямиллекләренә ирешәчәк булсалар, әлбәттә, бары тик бу юл белән, шундый бер усуль белән ирешәчәкләр.

Менә бу бөек максатка таба бер адым атлау, яки бөек бер капка ачып җибәрү өмете белән, Русия голямәләренә дә, таләбәләренә[1] дә иң дөрес мәгънәсе белән усул-ы фикъһыдан бер үрнәк күрсәтү нияте белән, Казанда «Сабах» китапханәсе быел «Әл-Мөвафәкать»не бастырырга кереште.

«Әл-Мөвафәкать» Андәлус голямәсеннән булган әл-имам әл-хафиз Ибраһим бине Муса әш-Шатыби хәзрәтләренең тиңе булмаган бер китабыдыр. Бүгеннән 25 ел элек һиҗри 1302 сәнәдә[2] Туниста бер мәртәбә басылган иде. Гадәттән тыш олы игътибар белән бастырган булсалар да, китапда берникадәр хаталар калган иде.

Бу юлы мин шул китаптагы ялгышларның төзәтелүен кирәк дип табып, Ходайның ярдәме белән, иҗтиһадта, игътибарда кимчелек күрсәтмичә, әүвәлдә калган хаталарны да төзәтеп чыктым. Ходайның һидаятенә[3] таянып өмет итәмен ки, китапның хәтта бер ноктасында да хата калмаячак.

Китапның укылышына беркадәр җиңеллек бирү өчен, җөмләләрне нокталар белән бер берсеннән аердым. Туры килгән урыннарда мөстәкыйль җөмләләрне һәрчак юл башыннан башлап җибәрдем. Мәсьәләгә бәйләнеше булган гыйльми нәрсәләрне әледән әле хашия[4] сурәтендә тәхтә әлхатт[5] яздым.

Дини мәдрәсәләребездә дини голүмнәр дәресләрен дөрес сурәттә ислях итү лязем икән, таләбәләребезгә аңлау сәләте,

---

[1] таләбә – дини гыйлем эстәүче шәкерт.

[2] һиҗри 1302 сәнәдә (ягъни һиҗри ел исәбе белән 1302нче елда) – әлеге дата милади ел исәбе белән 1884нче елга туры килә.

[3] һидаять – әйдәп бару; дөрес юл күрсәтү.

[4] хашия – мөселман дини әдәбиятенең бер төре: нинди дә булса дини китапка аңлатма рәвешендә (шәрех) буларак язылган китапка өстәмә аңлатма бирү; комментарий; биредә астөшермәдә бирелгән аңлатмалар мәгънәсендә кулланыла.

[5] тәхтә әл-хатт – төп текстның астында, ягъни астөшермәдә.

фикер куәте, мөстәкыйльлек һәм иҗтиһад рухы бирә алмаган «Мәнар»[1], «Тәүзыйх» кебек китаплар урынына «Әл-Мөвафәкать» кебек иң дөрес мәгънәдә усул-ы фикъһыны бәян итә, һәм дә talәбәләргә иҗтиһад кыйлу сәләте белән мөстәкыйльлек рухын сеңдерә торган бер китабны кабул итәргә кирәк. Юкса, дини мәдрәсәләребезне ислях кыйлу хәрәкәтләре безне канәгатьләндерерлек дәрәҗәдә җимешләр бирә алмаячак.

*Казан, 1327нче сәнә, рабиг-ы нәбәви 23тә*[2]

*Муса Җаруллаһ*

[1] «Мәнар» (منار) – китапның тулы исеме «Мәнар әл-әнвар фи усул әл-фикъһы». Милади 1310/1320дә вафат булган Әбү әл-Бәрәкәт Габдуллаһ бине Әхмәд бине Мөхәммәд эн-Нәсафи исемле шәригать белгеченең фикъһы методологиясе буенча язган китабы.

[2] Әлеге дата 1909нчы елның 13нче апреленә туры килә. Рабиг-ы нәбәви дигәндә Муса әфәнде Мөхәммәт пәйгамбәр (ﷺ) дөньяга килгән рабигыл-әүвәл аен күздә тота.

## «Рәхмәт илаһийә борһанлары»ннан[1]

Инсаннарның[2] табигый гомерләрен алтмыш-җитмеш ел чамасы кадәр бер вакыт дип санасак та, сирәк очракларда аерым кайбер кешеләрнең гомере йөзләргә ирешсә дә, тәкъдир үлчәме белән инсаннарның гомере дөньяның гомере белән чагыштырганда шулай ук сизелмәс кадәр бер мизгелдән генә гыйбарәт булып калыр.

Бу түбән дөньяда барлыкка китерелүнең башыннан бу минутка кадәр килеп киткән кешеләрнең күбесе, шөбһә юк, үзләренең бер мизгел кебек булган гомерләрендә рәхәтләренә нисбәтән мәшәкатьләрне күбрәк күргәннәрдер.

Бер мизгел кебек булган гомерләрендә һич рәхәт йөзе күрмәгән мескен кешеләр, математик микъдарларның һичбере белән чикләнелә алмаган мәңгелек хозурында, никадәр кырыс шартларда булсалар да, сурәтләнүенә генә дә һичбер инсанның йөрәге чыдый алмас дәрәҗәдә коточкыч газап белән мәңгелек сурәттә газапланачаклар икән, йә, ул вакыт Гафур Мотлак[3] Әрхам әр-рахимин[4] Аллаһ, Рабб әл-галәмин[5] хәзрәтләренең һәрнәрсәне үз эченә алган мәрхәмәте белән гомуми кичереүе кайларга киткән булыр? Бары тик бер мизгел кадәр вакытта гына рәхәт кичертеп, аннары миллиардларның миллиардлары кадәр гасырлар дәвамында [бәндәне] коточкыч сурәттә җәза-

[1] Чыганак: Муса Бигиев. Рәхмәт илаһийә борһанлары. Оренбург: «Вакыт», 1911. Б. 25–27, 80–85,

[2] инсан – Коръәндә кешене белдерә торган сүзләрнең берсе; «онытырга», «оныту» мәгънәсенә ия булган тамырдан ясалган исем, ягъни онытучан.

[3] Гафур Мотлак – һәрнәрсәне тулысынча гафу итүче (Аллаһның исеме).

[4] Әрхам әр-рахимин – Мәрхәмәтлеләрнең иң мәрхәмәтлесе (Аллаһның сыйфаты).

[5] Рабб әл-галәмин – Бихисап тере галәмнәрне Тәрбия итеп торучы (Аллаһның сыйфаты).

лаган зат, Әрхам[1], йә Рахим[2] була алырмы? Андый затның үч алуы, ярсуы чагыштыруны кабул итмәслек дәрәҗәдә аның кичерүеннән, мәрхәмәтеннән артык булмасмы?..

Мин бары тик шундый уйларга таянып кына да бөтен инсаниятнең коткарылачагы турындагы хөкемкә килгән булсам иде, галәме инсаният мәңгелек сурәттә, әлбәттә, җәзаланачак дип инанган кешеләрнең Ходайны тәгъзыймнәреннән[3], тәкъдисләреннән[4] Аллаһ Рабб әл-галәмин хәзрәтләрен мең мәртәбә артык тәгъзыйм вә тәкъдис иткән булыр идем.

Башка милләтләрнең һәрбере киләчәктә коткарылуны зур бер горурлык белән бары тик үзләренә генә хаслап калдыралар икән, мәңгелек хозурында бөтен кешелек дөньясының коткарылачагы турындагы тәгълимат исламиятнең игътикады ителә алса, андый бөек бер игътикад исламият өчен гаять олы бер фазыйләт[5] булмасмы?

Шөбһә юк, андый югары бер игътикад исламиятнең иң олы өстенлекләренең икенчесе була ала.

Кулымда һичбер дәлилем булмаса да иде, андый олы бер фазыйләтне исламиятгә булган мәхәббәтем этәрүе белән ислам тәгълиматы нигезенә урнаштырырга, әлбәттә, ифрат дәрәҗәдә иҗтиһад итәр идем. Мәгәр кулымда бу кадәр гаять ачык вә анык дәлил була торып, инде мин ничек дәшми калыйм ди?

<…> «Әл-Муәфәкать»нең сахибы[6] бу китапның 3 нче бүлегендә, «Шәргый дәлилләр» исемле өлешендә болай дигән: «*Коръән кәримдә куркыту айәтләренең һәрбере янында,– алдыннан булсын, артыннан булсын,– өметләндерү айәтләре искә алына. Ләкин һичбер айәтдә бу хөкем тормышка ашкан бер нәрсә буларак түгел, бәлки бер мөмкинлек буларак килә*».

---

[1] Әрхам – Иң мәрхәмәтле (Аллаһның исеме).

[2] Рахим – Рәхмәт / Мәрхәмәт Кыйлучы (Аллаһның исеме).

[3] тәгъзыймләреннән – олылауларыннан.

[4] тәкъдисләреннән – изгеләштерүләреннән.

[5] фазыйләт – яхшылык; игелекле нәрсә.

[6] сахиб – биредә: автор.

Мәсәлән, «Гасыр» сүрәсендә Аллаһ Рабб әл-галәмин хәзрәтләре димеш: *«Гасыр шәрәфе белән ант итәмен ки, кеше хәсрәттәдер, мәгәр иман итеп игелекле гамәлләр кыйлучылардан кала»*[1].

Биредә «кеше» дигәндә Аурупа халкы, ә ул кешеләрдән ясалган чыгарма исә Русия татарлары, дигән сүз түгел.

Коръән кәримдә Ниса сүрәсендә (141) айәт кәримәдә Аллаһ хәзрәтләре: (وَلَن يَجْعَلَ اللهُ لِلْكَافِرِينَ عَلَى الْمُؤْمِنِينَ سَبِيلاً)[2], дигән.

Биредә әүвәлгеләрдән Саксония инглизләре, икенчеләрдән дә Һиндестан мөселманлары, яки Мисыр игенчеләре күздә тотыла алмый. Өстәвенә, чынбарлык моның нәкъ киресе түгелме?

«Мәляикә» сүрәсендә 29 нчы айәт кәримәдә Коръән кәрим болай ди: (إِنَّمَا يَخْشَى اللَّهَ مِنْ عِبَادِهِ الْعُلَمَاء)[3], ягъни, «***Аллаһудан ялңыз галим бәндәләре генә хәвеф идәр***».

Биредә белем ияләре дигәндә Истанбул хуҗалары, Әзһар шәехләре, Һиндестан мәвләвиләре, Бохара дамуллалары, безнең Русия мөдәррисләре, татар муллалары күздә тотылмый.

«Әнбия» сүрәсендә 105 нче айәт кәримәдә Коръән кәрим болай ди:

(وَلَقَدْ كَتَبْنَا فِي الزَّبُورِ مِن بَعْدِ الذِّكْرِ أَنَّ الْأَرْضَ يَرِثُهَا عِبَادِيَ الصَّالِحُونَ)[4], ягъни: «*Зикер соңында Зәбурда яздык: бу Җиргә Минем игелекле бәндәләрем варис булачактыр*».

---

[1] Коръән, 103:1–3.

[2] Коръән, 4:141: «мөэминнәргә каршы Аллаһ карышучыларга (кяферләргә) һичкайчан да юл ачмаячак!» (А.Х. тәрж.).

[3] Коръән, 35:28.

[4] Коръән, 21:105.

Биредә «الصَّالِحُونَ»[1] дигәндә сүз Мисырның рифагыйлары[2], Мәгъриб сәнүсиләре[3], Истанбул каландарлары[4], Һиндестан фәкыйрьләре[5], татар суфыйлары, Әлмәт ишаннары, Бохара нәкышбәндиләре[6] турында бармый.

Аллаһ Рабб әл-галәмин хәзрәтләре Коръән кәримдә (وَكَانَ حَقًّا عَلَيْنَا نَصْرُ الْمُؤْمِنِينَ)[7] дигән.

Аллаһ Рабб әл-галәмин «мөэминнәр»[8] дигәндә кемнәрне күздә тоткан икән? Дүрт-биш инглиз кулында әсир булып калган алтмыш миллион кадәр Һиндыстан мөселманнарынмы? Һолланда[9] кулында коллык итүче Җава[10] мөселманнарынмы? Яки…

---

[1] الصالحون (әс-салихун) – игелек кыйлучылар.

[2] рифагыйлар (рифагыйчылар) – XII йөздә Әхмәт әр-Рифагый исемле суфый тарафыннан оештырылган һәм Мисырда киң таралыш тапкан тәсаввыф тарикате. Бу тарикать ияләре зикер ярдәмендә җеннәр чыгару белән танылган булганнар.

[3] сәнүсиләр (сәнүсичеләр) – 1837нче елда Мөхәммәт ибне Гали сә-Сәнүсидән (1787–1859) башланып, Либия белән Суданда 1969 елга кадәр идарә иткән хөкемдарлар токымы (династиясе), суфыйчылык агымы һәм аның тарафыннан үткәрелгән дини-сәяси хәрәкәтнең иярченнәре.

[4] каландарлар – сукбайча яшәүче вә һичнинди мал иясе булмаган суфыйлар.

[5] Һиндестан фәкыйрьләре – Һиндестан җирлегендә яшәүче һәм фәкыйрьлекне һәрнәрсәдән өстен күрүче суфыйлар.

[6] нәкышбәндиләр (нәкышбәндичеләр) – XIV йөздә Мөхәммәт Баһаветдин Накышбәнд әл-Бохарый (милади 1389-да вафат) тарафыннан оештырылган суфыйчылык тарикатенең иярченнәре.

[7] Коръән, 30:47 «мөэминнәргә ярдәм итү Безнең өстебездәдер».

[8] мөэмин – бу сыйфат фигыль сүз әмн тамырыннан ясалып, иман иясен, иман итүче кешене белдерә.

[9] Һолланда – Голландия (Нидерланд) иле. Үз вакытында бу ил Көньяк-Көнчыгыш Азиядә яшәүче мөселманнарның, шул исәптән Җава (Ява) утравында яшәгәннәрен дә, үзенең колониаль идарәсе астында буйсындырып изеп-талап тоткан булган.

[10] Җава – Ява утравы (хәзерге вакытта Индонезия җире).

Коръән кәрим хисапсыз айәтләрдә иманны мактаса да, «Бәдеъү әл-мәгарифи»[1] белән «Мелла Җәлал»да язылган мәсьәләләрне күздә тотмый.

Коръән кәрим «تاحلاص»[2], «تاريخ»[3] гыйбарәләре белән кешеләрне яхшы эшләр эшләргә чакырган икән, «игелекле гамәлләр» дигәндә Казан татар телендә тәсбих тартмак, һәр көн йөз мең мәртәбә салават укымак, «Касыйдә-и бөрдә»ләрне[4] гыйбадәт кыйлу максаты белән кабатлау кебек эшләрне күздә тотмаган.

Аллаһ Рабб әл-галәмин хәзрәтләре Коръән кәримдә һәрбер бәхет-сәгадәтне мөттәкыйларга[5] вәгъдә иткән икән, мөттәкыйлар дигәндә яшел чапан бөркәнгән, сары читек кигән суфыйларны, мөридләр[6] тәрбияләүче шәехләрне, тәкияләрдә[7] гомер итүче ахмакларны, дөньядан гафил булган заһидларны[8], намәхрам[9] йөзенә карамас изгеләрне дә күздә тотмаган.

---

[1] «Бәдеъү әл-мәгарифи» («Белемнең башлангычы») – тәүхид вә Аллаһының сыйфатларына багышланган кәлам китабы. Татар мәдрәсәләрендә киң кулланылышта булып һәм яттан өйрәнелергә тиешле булган әсәр.

[2] صالحات (салихат) – игелекле гамәлләр.

[3] خيرات (хәйрат) – хәерле эшләр.

[4] «Касыйдә-и бөрдә» «Ябынча турындагы касыйдә») – милади 1213 елда туган шагыйрь һәм имам әл-Босайринең Мөхәммәт пәйгамбәргә, аңа карата булган сөю хисләренә багышланган шигъри әсәре. Касыйдә – гарәп вә мөселман шигъриятенең бер жанры. Муса әфәнде бу төрдәге әсәрләрне искә алып, аларны уку аркасында савап казанырга һәм Аллаһ ризалыгына ирешергә теләгән халыкның дини наданлыгының ни дәрәҗәдә тирәнгә киткән булуына ишарә итә.

[5] мөттәкыйлар – тәкъвалылар, Аллаһ ризалыгы өчен гамәл вә гыйбадәт кыйлучылар.

[6] мөритләр – суфый шәехләреннән, ишаннардан гыйлем вә сабак алучылар.

[7] тәкия – суфыйларның берләшеп, җәмәгать буларак яши торган урыннары.

[8] заһид – Аллаһ хакына дөньядан ваз кичкән кеше.

[9] намәхрам – ир-кеше өчен никяхланырга яраган хатын-кыз.

Аллаһ Рабб әл-галәмин хәзрәтләре Коръән кәримдә (كُنتُمْ خَيْرَ أُمَّةٍ أُخْرِجَتْ لِلنَّاسِ تَأْمُرُونَ بِالْمَعْرُوفِ وَتَنْهَوْنَ عَنِ الْمُنكَرِ)[1] дигәндә, «Тәнбиһу әл-гафилинә»дән[2] «Дөррәтү әл-вәгыйзыйнә»дән[3], «Тәзкирату әл-Куртуби»дән[4] вәгазь сөйли торган имам вә хуҗалар[5], Мисырда басылган хөтбәләрдән берсен минбәрләрдә укый торган хатыйблар турында әйтергә теләмәгән.

Аллаһ Рабб әл-галәмин хәзрәтләре (وَمَن لَّمْ يَحْكُم بِمَا أَنزَلَ اللهُ فَأُوْلَـئِكَ هُمُ الْكَافِرُونَ)[6] дигәндә (مَا أَنزَلَ)[7] дән «Бәззазия»ләрдә, «Тәнвир»ләрдә[8], «Җамигу әр-рөмүзи»ләрдә язылган хөкемнәр турында әйтергә теләмәгән.

Аллаһ Коръән кәримдә җәннәт әһелләре турында да, җәһәннәм әһелләре турында да бәян иткән, ләкин, «ягъни Анатул төрекләре», ягъни «Америка инглизләре» димәгән.

Коръән кәримдә газап турындагы айәтләрне, яки мәрхәмәт турындагы айәтләрне укып дәлил буларак файдаланачак адәмнәргә бу нокта турында уйлану зарурдыр. Юкса,

[1] Коръән, 3:110 «сез кешеләр арасына чыгарылган иң хәерле өммәтсез: сез игелек кыйлуга чакырасыз һәм яман эшләр кыйлудан тыясыз».

[2] «Тәнбиһу әл-гафилинә» («Гафилләрне вәгазьләү») – милади 1003 елда вафат булган Әбү әл-Ләйс әс-Сәмәрканди исемле дин галименең әдәп-нәсихәткә багышланган күләмле әсәре.

[3] «Дөррәтү әл-вәгыйзыйнә» («Вәгазьләүчеләрнең җәүһәрләре») – 1825 елда вафат булган Госман Хопалы исемле галимнең әсәре.

[4] «Тәзкирату әл-Куртуби» («Куртубинең кисәтүләре») – 1273 елда вафат булган Андалусияле Мөхәммәт ибне Әхмәт әл-Куртуби (ягъни Кордовалы) исемле галимнең үлем вә ахирәт хәлләренә багышланган китабы.

[5] хуҗа – төрекләрдә дин сабагы укытучы мулла вә имамнарга ихтирам белдереп мөрәҗәгать итү сүзе.

[6] Коръән, 5:44 «Аллаһның иңдергәннәренә күрә хөкем итмәүчеләр карышучылардыр (кяферләрдер)».

[7] مَا أَنزَلَ (аның иңдерелгән нәрсәләре) – Аллаһның иңдергәне (Аллаһ тарафыннан Коръәндә иңдерелгән хөкемнәр һәм күрсәтмәләр).

[8] «Тәнвир» («Тәнвир әл-кулүб») – Мөхәммәт Әмин әл-Көрдинең (1914 ваф.) әсәре булуы ихтимал.

мәрхәмәт турындагы айәтләр – «Безгә генә!», газап турындагы айәтләр «Тегеләргә!» булып яңгыраган игътикад үзебезне алдаудан башка һичбер нәрсәгә хезмәт итми.

(واذا تساوى فى القبيح فعالنا)

(فمن التقى واينا الكفار؟)[1]

Күктән иңгән китапларның берсе белән бәйләнешләре булуны дәгъва иткән милләтләрнең күбесе харап булган булса, бары тик шундый бер игътикад тәэсире аркасында харап булган: күктән иңгән сөенчеләрне – бары тик үзләренә, кыямәт газапларын гел башкаларга каратып, күктән иңгән китапларда ул кадәр макталган иманны телдә йөртеп тә, тормышта исә әһәмияте булмаган бер-ике, йә өч-дүрт җөмләдән гыйбарәт булган бер нәрсә дип гөман иткәннәр. Ул ике-өч сүз белән белдерелгән нәрсәләргә дөрес сурәттә инанылган очракта, кешеләрне бәхет-сәгадәт юллары буйлап атлап баруга китерәсе урында, яшәеш белән бәйләнеше югалтылган ул сүзләр, киресенчә, кешеләрнең торгынлык түшәкләрендә ял итеп ятуларына сәбәп була килгәннәр. Бу хәлнең сәбәбе ни?

Коръән кәримдә «Фөркан» сүрәсенең ахырындагы айәтләрне укысак, Коръән кәримнең бу хакта ни дигәнен күрербез:

*«Рахманның бәндәләре – җир йөзендә тыйнаклык белән йөри торган бәндәләрдер. Үзләренә җаһилләр дәшсәләр, аларга пакь вә тугры сүз әйтеп җавап бирәләр. Раббыларына сәҗдә вә кыям кыйлып гомер итәләр. Чыгымнары булса, исраф кыйлмаслар һәм саран булмаслар, бәлки, һәрхәлдә, уртача булырлар. Ширек итмәсләр, гаепсез канны түкмәсләр, зинадан пакь калырлар, ялган нәрсәләргә шәһадәт бирмәсләр, файдасыз буш һәм вак нәрсәләр белән мәшгуль булмаслар, Раббыларының айәтләре белән уяу булырга чакырылсалар, колаксыз-күзсез берәү кебек игътибарсыз калмаслар; – Йа,*

---

[1] гарәпчәдән тәрҗемәсе: «Яманлык кыйлуда тигезләшкән замабыз / Кем диндар да, кайсыбыз кяфер – аңлашылырмы?» (Әбу әл-Галә әл-Мәгарринең «әл-Лөзүмият»еннән).

*Рабб! Безгә шатлык бирәчәк хатыннар һәм балалар бир! Безне тәкъвалыларга имам ит! – диярләр»*[1].

«Фөркан» сүрәсендәге ул айәтләрне һәрберебез укыйбыз. Ләкин күбебезнең аңлавына күрә, Аллаһның андый бәндәләре «мәчет картларына имамлык итүче, яшел чапаннар бөркәнеп йөрүче» карт хәзрәтләр, яки гомерендә дүрт-биш хатын алып яшәгән гаять мәһабәт карт ишаннардыр.

Беләмен ки, бу сүз гаять авыр сүз. Ләкин, ни кылыйк, бары тик безне генә түгел, бәлки һәммә милләтебезне, ул кадәр генә дә түгел, бәлки тулысынча исламиятебезне харап иткән бер бәладер бу бәла!

Гадел булыйк! Күңелебездә беркадәр генә иман калган булса, үзебезне дә, милләтебезне дә алдаудан беркадәр оялыйк инде!

Хәзергә шул.

---

[1] Муса әфәнде язылышында: «Рахманның бәндәләре – йир йөзендә сәкинә илә йөрер бәндәләрдер. Җаһилләр, анлара хитаб идәрләр исә, пакь тугры сүзи сөйләрләр. Раббыларына сәждә кыям идүб кичәрләр. Инфакъ идәр икән, исраф һәм саранлык итмәзләр, бәлки һәрхәлдә уртача улурлар. Ширек итмәзләр, мәгъсум кани түкмәзләр, зинадан пакь калурлар, ялан шәйләрә шәһадәт вирмәзләр, биһудә уфак шәйләрә тәнәззел итмәзләр, раббыларының айәтләрейлә тәзкир улынурлар икән, колаксыз-күзсез илтифатсыз калмазлар; – Йа, Рабб! Безә шадлык вирәчәк хатунлар, балалар вир! Бези мөттәкыйлара имам ит! – диярләр».

# Сәхәр кояшы[1]

Быел июнь 7 дә, төнге сәгать 12 тирәсендә, Петербург бакчаларының берсендә, ахшам гәзитләренең берсен укып, Лотфуллаһ әфәнде әл-Исхакый хәзрәтләре утыра иде. Мин дә Петербургның якты ак төннәрене күрү нияте белән чыккан идем. Очраклы рәвештә каршылаштык. Шәһәр гаять тын, һава гаять ачык; төнге сәгать унике; вак хәрефле рус гәзитләрен җиңел укыр кадәр яктылык. Гәзит хәбәрләре турында сөйләшеп алдык. Ахырда «батмас кояшны» күрү өчен карар кыйлынган сәфәребезне тәгайенләдек. Июнь 8дә[2] ахшам 8 сәгать 30 дакыйка поезды белән хәрәкәт кыйлачак булдык.

***

Хәрәкәтебезнең хатты[3]: Петербургдан Фин тимер юлы белән Торнау шәһәренә таба. Монысы, якынча, бер мең чакрым. Торнаудан Авасакса тавына, автомобиль юлы белән тагын җитмеш биш чакрым.

Авасакса тавы Төньяк гарызының[4] 66 дәрәҗә 26 дакыйкасында урнашып, диңгез тигезлегенә нисбәтән 330[5] аршин биеклеккә ия булган бер таудыр. Июнь аеның 9 ы, 10

---

[1] Чыганак: Муса Җаруллаһ Бигиев. Озын көнләрдә рузә. Казань: Электро-Типография «Умид», 1911. Б. 38–56. (Әсәр татар теленә тәрҗемә ителеп бирелә).

[2] 1910 елның 8 июнь көне яңа җәдвәл буенча 21 июньгә туры килә. Яңа җәдвәл (григориан календаре) 1918 елның 24 гыйнварында Халык Комиссарлары Советы Декреты белән кертелә. Шулай итеп иске җәдвәл (юлиан календаре) буенча килгән 1918 елның 31 гыйнварыннан соң, яңа җәдвәл башланып, көннәр исәбе 14 февральдән башлана.

[3] хатт – маршрут.

[4] гарыз – географик киңлек, параллель.

[5] 242 метр.

сы, 11 е[1], ягъни өч тәүлек тоташ батмас кояшны күрү өчен кешеләр ерак җирләрдән шунда киләләр имеш. Мөселман каләме белән язылган борынгы астрономия китапларында гыймарәтнең[2] чиге буларак кабул кыйлынган 66 дәрәҗә 25[3] дакыйка сызыгын кичү безнең икебез өчен аерым бер әһәмияткә ия иде. Шуңа күрә, Авасакса тавына сәяхәт итүне карар кыйлдык.

Ислам голямәсенең үзләренә мәгълүм булмаган, мөбарәк аяклары белән башына күтәрелүләр насыйп булмаган бер тауның очына менеп, табигатьтә сирәк очырый торган бер вакыйганы күрү безгә бер мәртәбә булыр кебек иде, зур бер тәэсирләнү бирәчәк кебек иде. Дин күзе белән карасак, безнең бу сәяхәтебез бары тик «шәфәкъ сүнми торган көннәрдә ястү намазы» хакында түгел. Бәлки өч намаз: ахшам, ястү, иртә намазлары хакында иҗтиһад сәяхәте булыр кебек иде.

Исламиятнең иң асыл рөкеннәренең берсе хакында соңгы сүзне, уразаның фарызлыгына кагылышлы изге шәригатьтә бар иң киң сүзне, үз күзең белән күргәннән соң әйтү теләге дә бездә бар иде. Ягъни мөкатдәс бер максат безнең теләгебезне ныгытты гына.

Бәрадәр Лотфуллаһ әфәнде әл-Исхакый хәзрәтләре җомга намазына үзенә алмаш тәгайен итте дә, июнь 8дә ахшам 8 сәгать 30 дакыйка поезды белән «Финляндия» вокзалыннан 3нче класста кузгалып киттек. Фин тимер юлында вагоннар гаять пакь, фин халкы әдәпне белә, хөрмәт саклый, тын, акырмас, бакырмас, кәеф кормас, табигатьләре гүзәл, киемнәре пакь халыкдыр. 3нче класс биреләрдә кешегә рәхәтсезлек бирмәс. Яман сүз, начар ис, әдәпсез хәрәкәтләр биредә бул-

---

[1] Яңа ел исәбе белән 22, 23, 26 июнь булыр иде.

[2] гыймарәт – кешеләр төпләнеп, өйләр, каралты-куралар салып яши торган урыннар; Җир шарының кеше тарафыннан даими яшәү өчен җайлаштырылган урыннары.

[3] Әлеге географик параллельдә җәйге озын көннәрдә кояш, 24 сәгать дәвамында күк йөзендә булып, һич баемый, ә кышкы озын төннәрдә 2 сәгать 47 минут дәвамында гына күренеп ала.

мый. Әдәп сөйгән, рәхәт эстәгән кеше Фин тимер юлында 3нче класста бара алыр, тарлык-кыенлык күрмәс.

Фин тимер юлында минем бу сәяхәтем икенче мәртәбә сәяхәт иде. 1910 ел көз ахырларында күрмәк-өйрәнмәк нияте белән мин ике атна кадәр вакыт фин шәһәрләрендә йөргән идем.

Әүвәлге сәяхәтемдә минем күзем фин җирләренең табигый хәлләренә, ягъни һавасына, суларына, тауларына, ташларына, агачларына, урманнарына, күлләренә, чайләренә[1] бакмас иде. Бәлки сазлык, ташлык җирләрдә безнең татарлардан, руслардан, казаклардан күпкә рәхәт гомер иткән финнарның иҗтимагый хәлләренә, ягъни өйләрендә тормышларына, җиһазларына, пакьлекләренә; йортларда, кырларда, фабрикаларда, заводларда эшләренә-көчләренә; дүкkәннәрдә[2], магазиннарда, базарларда сәүдәләренә, тиҗарәтләренә[3]; театрларда, кинематуграфларда, ресторaннарда, каһвәханәләрдә туплануларына-утыруларына; рухларына, ял сәгатьләрендә, бәйрәм көннәрендә урамнарда, мәйданнарда йөрүләренә, хәрәкәтләренә; кием-салымнарына, җәмгыятьләрдә[4], урамнарда хатыннарның-кызларның әдәпләренә, хөрмәтләренә, назсыз-тәкәллефсез[5] хәрәкәтләренә, сүзләренә; урамларның, юлларның, йортларның һәр җирдә гаять пакьлегенә, башлангыч, урта мәктәпләрнең җәннәт биналары кебек матурлыгына-пакьлегенә, һичбер җирдә мәйханәләрнең, трактирларның, хәерче-ялангачларның юклыгына, кием-салымда фәкыйрьләрнең-байларның бәрабәрлегенә[6], урам башларында сакчыларның азлыгына, кәнисә[7] хәрәмнәрдә[8] финнарның әдәпләренә, хо-

[1] чай – инеш, елга.

[2] дүккән – кибет.

[3] тиҗарәт – алыш-биреш, сәүдә.

[4] җәмгыятьләрдә – кешеләр җыелган җирләрдә, кеше күп булган урыннарда.

[5] тәкәллеф – ясалмалылык; кыйлану.

[6] бәрабәрлегенә – бергәлегенә, тигезлегенә.

[7] кәнисә – чиркәү-гыйбадәт

[8] хәрәм – изге урын, храм.

шугларына[1], эш сәгатьләрендә бакчаларның, мәйданнарның бушлыкларына, гомумән, баш күзе белән күренер иҗтимагый әхвәлләренә игътибар итә идем мин. Мин ул хәлләрен гаять бәгәнмеш идем[2].

Финнарны, гомумән, хатынларын-ирләрен, эш кешеләре [дип] булдым[3]. Эшләмичә көн күрү яки ялкаулык билгесе булган зәвыклы киемнәрне – ирләрдә, назлылык, эшсезлек күрсәткече [булган] ак-йомшак кулларны-бармакларны, мәүсем[4] модаларны хатыннарда, күрмәдем. Руслар җәмгыятьләрендә мәүсем модаларын ригаять итмәмәк[5] гаептер. Әмма финнар күзендә модаларга иярмәү гаеп түгел, бәлки ялангачлар, фәкыйрьләр барында купшы-зиннәтле киемнәр кию гаептер кебек күренде. Шуңа күрә булса кирәк, финнарның байлары-фәкыйрьләре кием-салымда улкадәр аермалылык күрсәтмиләр. Финнарда киемнең кыйммәтлеге могътәбәр[6] түгел, бәлки пакьлек могътәбәрдер.

Финнарның башка хәлләрен мин сорашып белә идем: финнарда ялган сөйләү, угрылык итү, хыянәт итү кебек нәрсәләр юк имеш. Мин моны үз күзем белән дә беркадәр күрә алдым: юлчылар вагоннарда һәммә нәрсәләрне калдырып китәләр, югалу ихтималыннан курку биреләрдә юк; поездларда нибары бер кондуктор була, билетсыз утыру, куянлык кыйлу финнарда һич юк имеш; трамвайларда билет бирү, билет тикшерү юк, һәр кеше үзе трамвай вагуннарының котуларына[7] тәгаейн кыйлынган акчаларны салып китә. Салмау, я биш тиен урынына өч тиен салу кебек ихтималлар, финнарның табигатьләрендә булган әманәт хөкеме белән гүя, аслән мөмкин түгел кебектер. Або шәһәренең трамвайларында финнарның бу хәлләрен һәм дикъкать белән, һәм соклану белән күзәттем.

---

[1] хошуг – күңел түбәнчелеге.

[2] бәгәнмеш идем – хушланган идем, ошаткан идем.

[3] булдым – таптым, күрдем.

[4] мәүсем – ел фасылы, сезон; бәйрәм, тантана.

[5] ригаять итмәмәк – кайгыртмау, исәпкә алмау.

[6] могътәбәр – хөрмәтле, хөрмәт ителә торган.

[7] коту – касса

Гаҗәпләндем, чөнки Истанбул, Мисыр, Русия тимер юлларының, трамвайларының хәлләре миңа мәгълүм иде.

Әүвәлге сәяхәтемдә Һелсингфорс шәһәренә барышлый, Лахти шәһәрендә дөньясы гүзәл Хәсән әфәнде өендә кунак булдым. Максатым Лахтида урта мәктәпләрдә алман, инглиз телләре мөгаллиме, төрек, рус телләрен яхшы белгән бер яшь профессорны зиярәт итү, һәм дә, мөмкин булса, беркадәр мәгълүмат алу иде.

Хәсән әфәнде – гүзәл мануфактура кибете тоткан һәм дә финнар күзендә гүзәл хөрмәтле булган яшь мөселмандыр, миңа кирәкле яшь профессорның да яхшы танышы имеш.

Бәрабәр профессор белән күрешергә киттек. Ихтирам белән безне кабул итте. Төрек телләренең сарыф вә нәхү кагыйдәләренә кагылышлы бер-ике кызыклы мәсьәлә сөйләде, китапханәсендә булган сирәк очрый торган әсәрләрне күрсәтте, соңыннан гафу үтенеп, кызлар гимназиясендә дәресләренә китте. Яшь профессор гаять гади гомер итүче, җанлы, тырыш бер адәмдер. Акшам 6 сәгать тирәләрендә визит кайтармак өчен безнең кунакханәбезгә килде. Өч-дүрт сәгать дәвам иткән сохбәтендә финнарның хәлләренә, тарихларына караган минем өчен гаять мөһим нәрсәләрне бәян итте. Кулында статистика да бар иде. Финларның мәктәпләренә, матбугатына, фәнни, тиҗари җәмгыятьләренә, ширкәтләренә, җитештергән туарларына кагылышлы иң соң хисаплар белән таныштырды.

Ике ярым миллион кадәр кешедән торган финнарның Америкада, Аурупада тиҗарәт итә торган бер мең биш йөз кадәр пароходлары бар икән. Америкага эш өчен һиҗрәт иткән фин эшчеләре өчен Америкада фин телендә унтугыз гәзитләре бар икән. Финляндиядә гомер идәр дүрт биң кадәр чинганәләр[1] өчен дә фин телендә бер гәзит нәшер кыйлына икән.

Балалар өчен белем алуның гомумилеге мәсьәләсендә профессор җәнабләре болай диде: «Белем алу бездә канун хөкеме белән мәҗбүри түгел, ләкин мөкатдәс динебез кушуы белән белем алу бездә фарыз кебек һәр кешенең үзенә кагылышлы вазифадыр».

---

[1] чинганә (چنگانه) – чегән.

Мин бу сүзне аңламадым, тәфсирен таләп иткәндәй дәшми тордым. Профессор җәнабләре диде: «Белеме булмаган адәмнең шәһадәте, дәгъвасы кабул кыйлынмый, мәдәни мөгамәләләрдә әһелият иясе була алмый, фин җәмгыятендә әгъза булу өчен белем кирәк».

Тәфсире әүвәлге сүзеннән тагын да сәер булып күренде. Мөкатдәс дин карашында белем алуның фарызлыгы – белеме булмаган, ягъни уку-язуны билми торган адәмнәрнең мәдәни хокуклардан, әгъзалыкдан мәхрүм булуы мәгънәсендә икән.

Диннәрен фин фәкыйһләренең букадәр гүзәл, букадәр тирән аңлауларына, чын мәгънәсе белән, хәсәд иттем[1].

Әңгәмәбезнең ахыры финнарда гаилә, тәрбия, җир, әдәбият мәсьәләләренә караган иде. Гыйлемнәре белән Аурупада шөһрәт казанган фин әдипләреннән Вестермарк, Махален, Рунаберг кебек затларның исемнәрене, хезмәтләрен дә бәян итте.

Төнге сәгать 12ләрдә яшь профессорны ханәсенә кадәр озатып, сәхәр сәгать 6 тирәләрендә Лахтидан Петербурга хәрәкәт иттем.

***

Әүвәлге сәяхәтем көз ахырларында иде. Фин җире ул вакыт карлар-бозлар белән тәмам капланган иде. Хәзерге сәяхәтебез яз[2] уртасында, июнь башларында. Әтраф тәмам яшеллек. Юлда гүзәл дачалар, урманнар, агар сулар, гүзәл күлләр, киң болыннар, басулар, ташлыклар, сазлыклар; берберсеннән аралары ерак түгел шәһәрләр-карьйәләр.

Безнең һичберебезнең фикерен-күзен фин җирләренең ул табигый хәлләре мәшгуль итми иде. Табигый хәлләренә дикъкать итә алмый яки итми идек.

Кырымның бакчаларын, Кавказ тауларын, Волга-Кама буйларын, Себер степьләрен, Төркестан, Гарәбстан, Африка чүлләрен, Шам, Сәмәрканд, Ташкәнд бакчаларын, Һиндыстан гаҗәъибләрен, Әфганстан тауларын, ташлыкларын, Пе-

---

[1] хәсәд иттем – көнләштем.

[2] яз – госманлы телендә җәйне белдерә.

тербург сазлыкларын күргән-белгән адәмнәргә фин җиренең ул табигый хәлләре, ташлыклары да, сазлыклары, әлбәттә, улкадәр кызыклы итеп күренмәз.

Фин җирендә бар мәгъдәннәрдән[1] тимерме, бакырмы, гранитмы, мәрмәрме порфирмы чыга, безгә ул җиһәте я һич мәгълүм түгел, яки безнең карашыбызда һичбер әһәмияте юк кебек иде. Безнең бар кадәр дикъкатебез – җир юк икән, җир иҗат иткән, ягъни Финляндия сазлыкларында, ташлыкларында үз көче белән иген җирләре иҗат иткән финнарның үзләренә, хәрәкәтләренә, тугрылыкларына, пакьлекләренә берегеп калган кебек иде. Сүзсез авызларына, уйлы башларына, эшлекле кулларына, хезмәткә күнеккән тәннәренә, сабыр итәр күңелләренә, мәшәкатьләрне, зур авырлыкларны җиңеп чыгу хакында әл-Мисак көнендә[2] бирелгән килешүләренә, иманнарына, маңгайларыннан яңгыр кебек аккан тирләре белән сугарылган җирләренә, пакь киемнәренә, өйләренә сокланып карый идек.

Безнең өчен «финнар кайдан, кайчан бирегә күчеп килмешләр? Җиде-сигез гасыр дәвамында ирексез калган финнар милләтләрен, телләрен ничек саклаганнар?» кебек мәсьәләләр улкадәр мөһим түгел иде. Сазлыкларны, ташлыкларны игенлеккә, бакчалыкка, урманлыкка әйләндерү чараларын тапкан финнар – милләтне, телне саклау чараларын, әлбәттә, табарлар. Финнарның букадәр тырыш һәм эшлекле булулары күзгә күренеп торганда, «Туфаннан соң милядкә кадәр[3], Азиядән күчеп биреләргә килделәр» сүзе кебек хыял тарихларының ни әһәмияте бар? Андый сүзләр кабинетларда гафиллек дакыйкаларында тарихчыларның киң хыялларына килер, әмма сазлыкларда-ташлыкларда исәпсез-хисапсыз мәшәкатьләр соңында барлыкка килә алган игенлек-бакчалыкларны күрүдән туган хәйран калу сәгатьләрендә андый хыяллар кеше башы-

---

[1] мәгъдән – табигый казылмалар, рудалар.

[2] әл-Мисак көнендә – Аллаһ тәгалә адәмнән туачак җаннар белән килешү (мисак) төзегән көн.

[3] Туфаннан соң милядкә кадәр – дөньяны су басканнан соң Гайсә пәйгамбәрнең тууына кадәр.

на килмәс. Эшлеклелек хыялларны түгел, бәлки эшне башкарып чыгу юлларын эзләтә.

Сигездән сигезгә кадәр хәрәкәт иттек, караңгылыктан бер әсәр юк иде. Поезд станциядән станциягә туктап-туктап бара иде, юлчылар бере төшеп калыр, бере утырыр иде. Театр пәрдәләре ачылыр-ябылыр кебек, безнең күзебездә манзаралар һаман-һаман яңарыр иде.

Табигать – билетсыз буш тамаша кыйлынур, иң гүзәл, иң бөек бер театрдыр. Табигать сәхнәләрендә күренер фаҗигаләр, гаҗәеп вакыйгалар, комедияләр – шагыйрьләрнең тар хыялларында түгел, табигатьнең киң, гаять киң мәйданнарында, охшашлану яки иярү юлы белән түгел, бәлки хакыйкать булу сыйфаты белән вакыйгъ була.

Поезд сәгать 11 чамасында Таммерфорс шәһәренә килде. Рихимәки, Туйаладан соң, безгә 3 нче дәфга биредә төшеп калырга кирәк, бу поезд Або шәһәренә китәчәк. Тугры Торнау шәһәренә төнге сәгать бердә хәрәкәт идәчәк поездны безгә биредә көтәргә кирәк иде. Таммерфорс кебек гаять гүзәл бер шәһәрдә, 13–14 сәгать тору безгә, бәлки, кирәк иде. Мәмнүниятлә[1] төштек. Таммерфорс мөселманнары – безне, без аларны яхшы белә идек. Станциядә Хәсән әфәнде Хәйретдинов туры килде. Ханәсенә киттек, берәр сәгать ял иттек. Телефон белән мөселманнарның күбесенә хәбәр бирде. Биредә һәр ханәдә, һәр квартирада телефон бар. Һәрбере белән күрештек, соңыннан бу гүзәл шәһәрнең тамашасына киттек.

Таммерфорс – фабрикалары, заводлары игътибары белән Финляндиядә иң беренче шәһәрдер. Фабрикаларның заводларның күбесе – Насиярви күленнән Пуһиярви күленә ага торган Тампәрәнкуски исемле иңәрсу (водопад) куәте белән эш күрер. Бу шәһәрдә бар кырык мең кадәр халыкның күбесе яки һәммәсе – фабрикаларда, заводларда, тиҗарәт идарәләрендә хезмәт итә торган халыктыр.

Урамнары, йортлары, бинлары гаять пакь бер шәһәрнең гүзәл бакчаларында, киң мәйданнарында киемнәри гаять пакь, ял сәгатьләрендә йөрешләре-хәрәкәтләре гаять әдәпле

[1] мәмнүниятлә – шатлык белән, ризалык белән.

эшчеләрне күрсә, кеше гаять зур ләззәт алыр. Канун исеме белән кягазьләрдә сакланган тигезлекне түгел, сәгадәт нигезе булган хакыйкый, гамәли бәрабәрлекне кеше биредә күрер дә, шат булыр.

Биреләрдә кеше – кирәге булмаган ясалма зиннәтләрне, кирәксезгә ялангач тәннәрне, эш авырлыгыннан йә эшсезлек кайгысыннан сәрхүш булган бәхетсезләрне, ялкаулык хәстәлеге белән кул сузып утырган мескеннәрне, наданлык йә фәкыйрьлек кушуы белән гыйффәт сатар хатын-кызларны, кадер хөкеме белән эшсез калган гаҗизләрне күрмәс. Бәлки эш бәрәкәте белән тәннәре сау-сәламәт булган, күңелләре шатлык белән тулган, куәт яңарту, яңа егәр тупламак өчен йөрер эшчеләрне күрер.

Кеше биреләрдә үзен бәхетле бер җәмгыять, гүзәл бер һәйәт инсания[1] эчендә хис итәр: гаделлектән туа торган иминлекне, иминлектән туар өметне, өметтән туар эшне, эштән туар рәхәт вә бәхетне һәммә тармаклары белән ачык сурәттә күзәтер.

Шәһәрнең мәктәпләрен, музей ханәләрен әүвәлге мәртәбә сәяхәтемдә фин телен белгән Хәйретдин әфәнде Хөснетдинов ярдәме белән тамаша иткән идем. Тел юклык аркасында нәрсәне дә булса аңлау, әлбәттә, мөмкин түгел иде, ләкин баш күзе белән күренер җиһәтләре, чагыштыру юлы белән мәгълүм була алган хәлләре, минемчә, гаять гаҗәеп иде. Русия школаларын, гимназияләрен, Төркия мәктәпләрен, игъдадларын[2] мин яхшы беләм. Фин мәктәпләрендә бар пакьлекне, нәзафәтне[3], иркенлекне мин һичбер җирдә күрмәдем. Идәннәре, диварлары тәмам көзге кебектер. Берничә мәктәптә идәннәрен бармакларым белән сөрттем – тузаннан бер әсәр табалмадым.

Шәһәрнең базарларын, тышкы манзараларын тамаша иттек дә, Гыймадетдин әфәнде Җәмалетдинов ханәсендә Кәмалетдин әфәнде Байбулатов, Хәсән әфәнде Хәйретдинов,

[1] һәйәт инсания – кешеләр җәмгыяте.

[2] игъдад – уку курслары; һөнәр мәктәбе, училище.

[3] нәзафәт – пакьлек, чисталык.

Әхмәтҗан әфәнде Җәмалетдинов, Фәттахетдин әфәнде кебек Таммерфорс мөселманнары белән туплandык. Гади бер гүзәл сохбәт булды. Финляндия, аеруча, Таммерфорс мөселманнарының тырышлыгы белән Яңапар карьясендә кызбалалар өчен үткән елда ачылган мәктәпнең яхшы сурәттә дәвамына, ул яңа мәктәп тәэсире белән башка каръяләрдә кыз балалар өчен ачылган һәм ачылачак мәктәпләргә кагылышлы матур сүзләр сөйләнде. Яңа мәктәпләрнең гүзәл җимешләрен, яшь мөгаллимәләрнең гүзәл иҗтиһадларын күргән Нижний мөселманнарының кыз балалар мәктәбенә теләкләре, мәхәббәтләре кат-кат артмыш, моның белән мәктәпләрнең киләчәге беркадәр тәэмин кыйлынмышдыр.

Таммерфорс мөселманнары Нижний вилаятеннән сәүдәтиҗарәт эшләре белән Финляндия шәһәрләренә килеп, финнар күзендә ышаныч казанган яшь, гүзәл мөселманнардыр. Биредә яшәгән мөселманнар һәрьяклап, ягъни хаклык, пакьлек, иҗтиһад, әманәт, икътисад, тырышлык кебек җиһәтләрдә, финләшкән мөселманнардыр.

Таммерфорс мөселманнарында матбугат укуга теләк гаять зур. Русиядә нәшер кыйлына торган матбугаттан: газеталар, журналлар, зур-кечкенә китаплар, рисаләләр – һәммәсе бар. Сәяси һәм көнлек хәбәрләрне фин җәридәләрендә укып торган Финляндия мөселманнары, моның тәэсире белән булса кирәк, Русиядә булган һәммә җәридәләрдә, журналларда катнашалар, гарәп, фарсы, төрки телләрдә нәшер ителгән һәммә китапларны алалар. Ислам матбугаты күплеге ягыннан Таммерфорс шәһәре Финляндия мөселманнары өчен бер кыйраъәтханә[1] кебектер.

Июнь 9-да акшам сәгать 8 чамаларында Гыймадетдин әфәнденең бәрадәре Лотфулла Җәмалетдинов имзасы белән Рованиемидән телеграм алдык: «Бирегә килегез, кояш күренә» дигән. Яхшы булды. Җитмеш биш чакрымны фин машинасы белән таш, тузан арасында барудан котылдык. Моның өстенә, Рованиеми, нинди генә булса да, бер каръядер,

[1] кыйраъәтханә – уку залы.

Авасакса тавы кебек кырда-сахрада түгел, гарызы да Авасакса тавындан артыктыр. Поезд да шунда кадәр бара.

Ровениеми минтака мөгътәдилә[1] чигендә минтака баридә[2] башланган урында төзелгән бер карьядер, гарызы 66 дәрәҗә 30 дакыйка кадәрдер.

Вакыт җитте, тордык, киттек. Озаттылар. Поезд нидәндер, кичекте. Беркадәр көттек. Килде, аманлашып[3] киттек. Юл озын, поезд егерме сәгатьтән артык хәрәкәт идәчәк. Дүрт марка биреп ике плацкарт алдык. Сәхәр вакытында калыккан кояшка протест белдергән кебек, юлчылар яттылар, йокладылар. Беркадәр ял иткәннән соң тордылар.

Биреләрдә станцияләр сирәк түгел, еш. Күбесе кечкенә була. Һәр станциядә финнар үзләренең эшләнмәләрен, ни бар исә, юлчыларга сатарлар. Ул көннәр финнарның бәйрәме иде. Станция кайнашында күңел ачар нәрсәләр безнең өчен дә табыла иде.

Төш вакыты җитте. Буфеты бар станцияләрнең берендә поезд иртәнге аш ашалырлык кадәр вакытка туктады. Юлчылар – станциягә, мин дә аларга иярдем.

Буфет яхшы, гаять пакь, финнарга хас гадилек. Зал зур, уртасында озын табын. Өстендә унбиш-егерме табак тулы төрле тәгамнәр тора. Гарсуннар, официантлар юк. Буфетта чәй бар, каһвә кебек нәрсәләр бар, ләкин шәраб фәлан юк. Чәй-каһвә бирү, акча ваклау өчен буфет артында ике өч гүзәл, хатун йә кыз тора. Залда тын, тавыш юк. Юлчылар кулларына вилка, кашык, тәлинкә алганнар да, иштиһаларына[4], зәвыкларына күрә, табаклардан никадәр теләсә алып китә, ашый. Һәр адәм табынны иштиһасына күрә, бер тапкыр, ике тапкыр әйләнеп чыга. Сак юк. Ул кадәр кеше кайнашында кем ашаган, кем ашамаган, никадәр ашаган, белгән юк. «Ашадың, инде акча бир!» дип торган кеше дә юк. Безнең мәмләкәт табигатенә күрә гаять сәер хәлдер. Гаҗәпләндем. Никадәр гүзәл әманәт-

---

[1] минтака мөгътәдилә – урталык буй (умеренный пояс).

[2] минтака баридә – салкын буй (холодный пояс).

[3] аманлашып – хәерле теләкләр белән хушлашып.

[4] иштиһә – теләк; аппетит.

тер! Тәгам ашаган вояжерларның һәрбере килде, акчаларын бирде, китте. Бирмәгәннән сорап алу юк, ләкин ашаган икән, биреләрдә бирмәү дә юк. Дөрес, финнарда безнең кебек хаиннәр була ала, ләкин Финляндиядә хакимлек иткән гомуми әманәт рухы хаиннәрне дә калдырмый, ягъни хыянәтләренә юл куймый, хаиннәрнең үзләре дә хыянәт итәргә батырчылык итә алмас була. Илнең рухы нинди исә, бернең рухы да, әлбәттә, шундый була.

Вояжерларны тамаша кыйлып ашсыз калсам да, яхшы бер сабак алдым. Хәзер ашамасам, зарар юк. Моннан соң юлда мондый гүзәл буфет тагын туры килә калса, юлчыларны тамаша кирәк түгел, бәлки бер марка бирермен дә, фин ашларының иң ләззәтлеләрен «татарча», ягъни сәхәр ашы кебек һәм туймак, һәм запас алмак өчен яхшылап ашармын, дидем дә, поезд тарафына ашыктым.

Киттек, юлда гаять гүзәл буфетлы станцияләрдә туктадык исә дә, юлчыларны тамашадан бушамадык. Ниһаять, акшам сәгать ун чамасында Торнау шәһәренә җиттек.

Торнау – Балтыйк диңгезенең иң төньягында кечкенә бер утрауда, Торнау исемле бер елганың тамагында, Русия белән Швеция чигендә урнашкан уфак бер шәһәрдер. Торнау елгасының икенче тарафында Швеция шәһәрләреннән Хапаранта исемле кечкенә бер шәһәр бар. Бу ике шәһәрдән һәрберен сәгать 12дән соң тамаша иттек. Безнең өчен әһәмиятләре юк иде. Кайттык, станция янында бер фин ханәсендә ял иттеки. Сәгать җидедә китәр поезд белән Рованиеми каръйәсенә киттек. Биредән йөз илле чакрым кадәр иде. Ун-унбер сәгать чамасында Ровениемигә җиттек. Муса Кәлимулла исемле бер яшь сәүдәгәр белән Лотфулла әфәнде Җәмалетдинов безне биредә каршы алдылар. Ул көн июньнең унбере, шимбә көн иде.

Рованиеми каръйәдер, ләкин гүзәл карьйәдер. Базары бар, урамнар пакь, яхшы мөсафирханәләр бар. Без аларның берсендә урнаштык. Бүлмәбез киң, пакь, якты иде. Моның белән бәрабәр бәясе бер марка иде.

Акшам сәгать ун чамасында Муса әфәнде, Лотфулла әфәнде Җәмалетдиновлар белән дүрт аркадаш булдык та, Рованиемидән өч дүрт-чакрым ераклыкта урнашкан бер тау башына киттек. Сәхәр кояшын күрү өчен баручылар аз түгел, күп иде. Һәр ел июнь уннан егермесенә кадәр бирегә туристлар батмый торган кояшны күрү максаты белән киләләр-китәләр икән.

Кечкенә бер пароход белән андагы елганы кичтек, бу тарафта җәяү бардык, юл яхшы иде. Тау юлы да ул кадәр текә түгел, бәлки сузак иде. Кыенлыксыз, мәшәкатьсез мендек, тауның иң очына чыктык. Озынлыгы дүрт-биш сажин багана башына гаять зур бер «бочка», мая буларак булса кирәк, утыртылган иде.

Зур булмаган бу тауның очыннан әтрафны тамаша иттем. Ерак түгел Рованиеми каръясендә бар завод-фабрикаларның морҗалары, кәнисә манарасы җир белән бәрабәр кебек күренә иде. Күк йөзе ачык, офыкта куе болыт. Сәгать унбер-кырык. Табигатьтә тынлык. Тавыш йук. Тынычлык! Төн уртасы. Кояш офык өстендә исә дә, кош-корт һәммәсе ял итәләр.

Тау башында финнардан, туристлардан, экскурсантлардан алтмыш-җитмеш кадәр халык.

Төнге сәгать 12. Кояш болыт артында, ләкин өске тарафы яңа туган ай кебек, кызган кызарган сәер төстә күренеп тора.

Берничә секундмы, берничә минутмы туктап торган кебек, кояш батмыйча, күтәрелмичә һаман шул хәлдә калган кебек!

Секундларны минутларны исәпли алмадык, бердән-бергә калыккан кебек кояш балкып торды. Кузгалып китте. Әтрафта ни бар исә, һәммәсе җанланды: саба җиле исте, кош-корт сайрый башлады, батмас кояш шәрәфенә туристлар учак яктылар, шишлекләр пешерделәр, «Ура!» кычкырдылар.

Тау башында торган җиде-сикез мөселман, рухи бер дәһшәтнең тәэсире белән булса кирәк, һәйбәт илаһия[1] хозурында тәъәддеб иткән кебек[2] тынсыз, тавышсыз! Дөмбәстә[3].

[1] һәйбәт илаһия – илаһи бөеклек.

[2] тәъәддеб иткән кебек – әдәплелек күрсәткән кебек.

[3] дөмбәстә – тораташ кебек катып калу.

(وَخَشَعَتِ الْأَصْوَاتُ لِلرَّحْمَنِ فَلَا تَسْمَعُ إِلَّا هَمْسًا)[1]

Астрономнарның фаразлауларына күрә, кояшның алты миллиард мөраббәгъ километр[2] кадәр йөзе, Санигъның газамат каһирәсе[3] белән чагыштыру шомлыгы белән булса кирәк, кызган-кызарган гади кечкенә бер таба кебек булып калды!

Куәте йөзләрчә планеталарны, хисабы юк койрыклы йолдызларны үзенең мәркәзендә какшамас тәртиптә әйләндереп тоткан бу ут шары – бу кояш илаһи газамат михрабында сәҗдә иткән кебек, вазифасын дәвам итү өчен калыккан да, офык буйлап, тетрәп хәрәкәт итә кебек!

Борынгы заманнарда мәдәният башларында үзенә гыйбадәт ителә торган зур мәгъбүд[4] булган ул кояш – бу сәгатьтә безнең аякларыбыз астында, балалар уенчыгы, бәләкәй бер туп булган да, аяк тибүеннән тәгәрәп китте кебек!

Ниһаяте чиге юк галәме вөҗүдтән[5] гыйбарәт булган Гареш Әгъзам[6] хәрәмендә, иң катгый тәртипкә корылган сафлар рәвешенә китерелгән йолдызлыклар җәмәгатендә имам булып, Халикъның[7] газамат илаһиясе михрабында ике тезенә чүккән (الجاثى على ركبتيه)[8] йолдызына бу безнең кояш оеп тәкбир әйтеп сәҗдә иттектән соң калыкмыш та, бетмәс-төкәнмәс илаһи

---

[1] «Барлык тавышлар Рахман хозурында хошугъ кыйлып буйсындылар һәм пышылдаудан башка син һичнәрсә ишетмисең» (Коръән, 20:108).

[2] мөраббәгъ километр – км$^2$

[3] Санигъның газамат каһирәсе – Барлыкка китерүченең һәрнәрсәдән куәтлерәк булган олуглыгы.

[4] мәгъбүд – үзенә табыныла торган нәрсә: мөселманнарда мәгъбүд – Аллаһ; потпарәстләрдә мәгъбүд – агачтан-таштан кырып ясалган потлар, сыннар.

[5] галәме вөҗүд – барлыкка китерелгән матди һәм матди булмаган нәрсәләрдән торган галәм.

[6] Гареш Әгъзам – Олуг Тәхет.

[7] Халикъ – Барлыкка китерүче, Холыкландыручы Аллаһ тәгалә.

[8] тәрҗемәсе: Ике тезенә тезләнгән. Геркулес йолдызлыгының гарәпчә исеме.

хәзинәләрдән файдаланыр өчен алып торган кызулыгын һәм нурын үзенең мәнзумәсендә[1] таратырга ашыга кебек!

Аллаһның җәляле[2], кибриясе[3], галәме вөҗүднең киңлеге, бөеклеге турында хикәят итә торган нәбилек телендә килгән хәдисләрнең тәэсире белән, калебебезне шул минутта шундый хис яулап алган иде.

Бу кояш, Халикъның газамат илаһиясенә нисбәтән бер зәррә генә булса да, йолдызлар галәменең ахыры юк киңлегендә юкка чыга торган бер нокта булса да, безнең акылыбызга күрә, безгә мәгълүм булган үлчәмнәргә күрә, ул кояшның җисеме, нуры, кызулыгы акылга сыйдыра алмаслык дәрәҗәдә бөектер.

Кеше фикерен бу җиһәткә юнәлтсә, кешене, чын мәгънәсе белән, дәһшәт[4] алыр!

Йөзләрчә планеталарны, хисабы юк койрыклы йолдызларны үзенең әйләнәсендә әйләнергә мәҗбүр иткән ул куәт – никадәр һаъил[5] куәтдер!

Һәр минутта хисабы юк кызулыкны, ниһаяте юк нурны тирә яктагы галәмдә туктамастан таратып торган кояш – исәпләп бетергесез гасырлар дәвамында бетмәгән ул кадәр кызулыкны, ул кадәр нурны кайдан ала?

Ул кадәр көчле кызулыкта яну аркасында көл булудан сакланып кала алган матдә, гаҗәп, нинди матдәдер?

Ягулык маддәсе ихтиракыясе кояшның үзеннән хасыйль булса, җисеменең күләме никадәр булса да, миллиард гасырлар-дәверләр дәвамында ул дәһшәтле кызулык ничек сүрелми кала ала?

Мондый нәрсәләрне уйлаганда, минем фикерем гаҗиз булып кала.

Бу күренешләргә карата, таныйк ки, фәннең, мәгарифнең «бер көн килер, ихтимал, мәгълүм булыр», диюдән башка бер җавабы бармы?

---

[1] мәнзумә – система, биредә Кояш системасы.

[2] җәлял – олы куәтлелек.

[3] кибрия – зурлык, олуглык.

[4] дәһшәт – курку, тетрәнү.

[5] һаъил – бик куркыныч, коточыргыч; иләмсез зур.

Аллаһның газамат илаһиясенә тәсбих буларак, мәгарифнең дәһшәт теле белән, үз үзеннән әйтелгән бер сүзе бар:

«Йолдызлар галәменең ниһаяте юк иркенлегенә нисбәтән бер зәррә кебек булган бу кояш – безнең җиребездә, ягъни көррә арзыябездә бар булган һәммә нигъмәтләрнең чыганагыдыр».

Дөрес, җир йөзендә бар һәммә нигъмәтләр, ягъни: мәгъдәннәрнең килеп чыгышы, үсемлекләрнең, хайваннарның хәятләре-хәрәкәтләре, һәммә куәтләре, кешенең үзе, күзе, мие, һәммә әгъзасы, кешенең ашавына, киеменә, һәммә хаҗәтләренә сарыф кыйлына торган һәм дә һәммә рәхәтләрен тәэмин итә торган җирнең бетмәс-төкәнмәс бәрәкәте, җирләрнең-суларның, океаннарның хәрәкәтләре, ел фасылларының алмашуы, яңгырларның явуы, инсаният галәменә һәм әүвәлләрдә, һәм хәзер дә хезмәт итә торган кызулыклар, нурлар, электрикалар, гомумиләштереп әйтим, җирнең үзе, җирдә бар куәтләрнең җәмгысы бергә кояштан бер зәррәдер.

Дәһшәт теле белән мәгариф моны әйткән, мәгариф әһеле моны һәммә фәннәрнең нәтиҗәсе буларак кабул иткән. Ләкин утка табынучы мәҗүсиләр, кояшка гыйбадәт итә торган борынгы диннәр бу хакыйкатьне тагын да элек тапканнар, җир йөзендә бар һәммә куәтләрнең, хәятләрнең, фикерләрнең чыганагы кояш булу хакыйкате ул мәҗүсиләрнең, һиндуларның гыйбадәтләре белән тагын да үтемле сурәтдә белдерелгән.

Мәгариф әһеленең горефләренә без дә ияреп, мәҗүсиләргә, һиндуларга, борынгы диннәргә карата «вәхшиләр» сүзене кулланыйк.

Ул «вәхшиләр» миллион зәхмәтләр нәтиҗәсендә сезгә мәгълүм булган ул бөек хакыйкатьне үзләренең гыйбадәтләре белән гаять гади сурәттә белдергәннәр түгелме? «Вәхшиләргә» борынгыдан мәгълүм бер гади хакыйкатьне шәрех итә алу шәрәфе – миллион зәхмәтләр соңында фәнегезгә бары тик бүген насыйп була алды түгелме?

Без, табигатьне гаять яхшы аңлый торган мәгариф әһеленең Халикъны инкяр итәр дәрәҗәдә башбаштаклыкларына иярмибез; өлүһиятне таләп итүдә мәҗүсиләр, һиндулар, бо-

рынгы диннәр кебек урта юлда туктап та калмыйбыз; бәлки табигатьнең дә, табигатьтә бар зур-кече кояшларның да Халикы Аллаһ раббел-галәмин хәзрәтләренә исламият күрсәтүе белән гыйбадәт итәбез. Ниһаяте юк галәме вөҗүднең Халикына, галәме вөҗүднең вак зәррәсе белән безгә бетмәс-төкәнмәс бәрәкәтләр, хисабы юк нигъмәтләр бүләк итеп, безне нигъмәтләндереп торыр Кәрим Мотлак Аллаһу раббел-галәмин хәзрәтләренә без мәңгелек сурәттә сәҗдә итәбез.

Мин, хәят, нур чыганагы булган кояшка гыйбадәт итә торган «вәхшиләрне» тәсъвиб идәрем[1], яки, кимендә, тәсъвиб итә алам. Ләкин шәфәкъ юкка чыкмый торган төннәрдә ястү намазы турында берсенә берсе каршы килгән «фәкыйһларны», андый төннәрдә намазлыкка утырып та Ходасына сәҗдә итүдән йөз чөергән[2] гафилләрне тәъсвиб итә алмыйм. Диннең рухыннан шулкадәр гафил булган дәрвишләргә мин гаҗәпләнәм.

***

Бик урынлы булмаса да, шәкертләргә, ихтимал файдасы булыр дигән өмет белән, Шариг кәбир, Нәбийе ислам, галәйһис-саләт вәс-сәлам, хәзрәтләреннән расланган бер сөннәт хакында фикеремне, һәм дә фәйләсүф-е ислам Әбү әл-Галә хәзрәтләренең мәсьәләбезгә бәйләнеше булган бәетләрене мин биредә яздым.

Фәйләсүф Әбү әл-Галә хәзрәтләре «әл-Лөзүмият»тә болай дигән:

(اذا مار أيتم عصبة هجرية) (فمن رأيها للناس هجر المساجد)
(وللدهر سر مرقد كل ساهر) (على غرة او موقظ كل هاجد)
(يقولون تأثير النجوم مغير) (من الدين آثار السراة الاماجد)
(متى ينزل الامر السماوى لايفد) (سوى شبح رمح الكمى المناجد)
(وان لحق الاسلام خطب يغضه) (فما وجدت مثلا له نفس واحد)
(وان عظموا كيوان عظمت وحدأ) (يكون له كيوان اول ساجد)

[1] тәсъвиб идәрем – дөрес дип табам.

[2] Кайбер фәкыйһләрнең фикеренчә, шәфәкъ яктысы бетми торган җирләрдә ястү намазы укылмаска тиеш, имеш. Муса әфәнде, шушы хөкемгә ияреп, ул намазны укымый калучыларны күздә тота.

Ягъни, «Бер йә аннан да күбрәк намазларның вакытларын таба алмыйча, кешеләрне мәчетләргә кертмәгән фәкыйһлар кебекләрнең яман тәсирләре белән исламият башына бәлаләр яуса да, исламиятнең тиңе һаман табыла алмады. Гыйбадәт итү йөзеннән яки уңыш китерер дип ышанып йолдызларны олыласалар, мин ул берәүне олылыймын ки, чөнки йолдызлар, иң әүвәл, аның үзенә сәҗдә итәрләр. Диннең бөекләрдән калмыш гадилеге, гүзәллеге йолдызлар аркасында үзгәрер, диләр. Юк сүз! Йолдызлар аркасында түгел, бәлки дин рухыннан гафил булган «фәкыйлар», иман югарылыгыннан гафил булган мөтәкәллимнәр аркасында булса булыр. Дәһрилекнең уяуларны йоклата торган, йоклаганнарны уята торган гаҗәеп дәһшәтләре, мәгълүм булмаган шундый серләре бардыр ки, хәкимнәрнең хикмәте, бәһадирларның куәте ул сәгатьтә бер файда бирмәс».

Фәйләсүфнең югарыда язылган сүзенең мәгънәви тәрҗемәсе будыр. Йолдызларны олылаган табигать габидләренә[1] юл күрсәтү хакына, вакытлары кермәү уйдырмасы белән берничә намаздан, мәчетләрдән кешеләрне мәныг итә торган фәкыйһларны кире кагу юлында әйтелгән гаять гүзәл сүздер.

***

Батмас кояшны тау башында, тамаша иткәндә, бер ноктада, бер минутта һәм горубның, һәм толугның[2] очрашуына бәйле сурәттә, «өч вакыт намаздан тыю» хакында әйтелгән хәдис хәтеремә килде.

Имам Мөслим бин әл-Хәҗҗаҗ хәзрәтләре сәхабә Гокбә бин-е Гамир хәзрәтләрендән риваять итмеш:

(ثلاث ساعات كان رسول الله صلى الله عليه وسلم ينهانا ان نصلى فيهن, وان نقبر فيهن موتانا: ١) حين تطلع الشمس بازغة, حتى ترفع; ٢) وحين يقوم قائم الظهيرة حتى تزول الشمس; ٣) وحين تتضيف الشمس للغروب).

Ягъни: өч сәгатьдер ки, нәбий-е ислам безне ул сәгатьләрдә намаз укудан, җеназа укудан тыя иде: 1) кояшның

[1] табигать габидләре – табигать күренешләренә табынучылар.

[2] һәм горубның, һәм толугның – кояш батуының да, калкуының да.

калыккан минутыннан күтәрелгәненә кадәр, 2) төш вакытында эссенең куәтләнүе сәбәбе белән дөяләрнең торып басуларыннан кояшның зәваленә кадәр, 3) баюга якынаеп кояшның баюына кадәр.

Бу хәдис мәшһүр мәзһәб имамнарының һәрбере тарафыннан кабул кыйлынмыш. Дөрес, мәзһәбтә фикер төрлелеге бар. Имамнар имамы Әбү Хәнифә, разыя Аллаһу ганһу, хәзрәтләре хәдиснең гомуме белән гамәл итеп, шул өч вакытта кәраһәттән[1] һичбер саләтне[2] чыгармаган, әмма башка имамнар бу хәдисне – үзара кушылган йә аңарчы килгән бер сәбәбе булмаган нафиләләргә хаслап казаларны; тәхиййәт, тилявәт, гает, көсүф[3], җеназа кебек нафиләләрне чыгармаганнар.

Шу өч вакытда намазның көчләп тыелуы ни өчен соң?

Фәкыйһларның иҗтиһадына күрә, ул сәгатьләрдә гыйбадәтләрен кыйлган табигать габидләренә яки башка милләтләргә гыйбадәтләргә охшашланудан саклану өчен имеш. (ما حرم سدا ًللذريعة, يباح للمصلحة الراجحة. من ذلك نهيه عن الصلاة قبل طلوع الشمس وقبل الغروب, سدأ لذريعة التشبه. واباح ما فيه مصلحة راجحة من قضاء الفوائت والسنن, والجنازة, وتحية المسجد. لان مصلحة فعلها ارجح من مفسدة النهى)[4].

Бу хәдис турында, һәм дә иҗтиһад әһелләренең бу аңлатулары турында беркадәр уйга калдым, фикер йөрттем. Иҗтиһад әһеленең аңлатулары минем карашыма күрә улкадәр мәгъкуль түгел кебек иде. Кояшка гыйбадәт итә торган габидләрнең сәҗдәләре – кояшның, табигатьнең Халикы Аллаһ раббел-галәмин хәзрәтләренә мөэминнәрнең сәҗдә итүләренә ничек комачау була ала?

---

[1] кяраһәт – көчләп тыелу.

[2] саләт – бәйләнештә булу; бу төшенчә, гадәттә, намаз сүзе белән алмаштырыла.

[3] көсүф – кояш тотылу.

[4] тәрҗемәсе: «Кояш чыгар яки батар алдыннан намаз уку аларга (потларга табынучыларга) охшашланмас өчен тыелган. Бу тыюда бәян ителгәнне үтәү, үтәлми калганны яки сөннәттә васыять ителгәнне, ягъни җеназа һәм тәхийятел-мәсҗидне каза кыйлудан хәерлерәк. Чөнки тыелганны үтәүнең мәсълихәте ул тыюдан килгән зыяннан өстенрәк».

Комачау һәрвакыт көчлерәк булып чыга түгелме?

Табигатькә табынучылар табигатькә сәҗдә иткән сәгатьләрдә табигатьнең Халикына сәҗдә итү мөэминнәр өчен тагын да яхшырак булмас идеме? Йә дөрес юл күрсәтү яки, кимендә, каршылык белдерү булыр иде.

Миңа калса, Шәргъ шәрифнең бу өч сәгатьтә гыйбадәттән мөэминнәрне намаз укудан тыюы – табигатькә табынучыларны беркадәр икърар[1] кебек булса кирәк. Әһле китапны ислам шәригате икърар итә икән, табигатькә табынучыларны да, әлбәттә, икърар итә ала.

Табигатькә табынучылар, мәсәлән, кояшка сәҗдә итсәләр, әлбәттә, кояшның илаһилегенә инанулары тәэсире белән сәҗдә итәләр.

(وَقَضَى رَبُّكَ أَلاَّ تَعْبُدُواْ إِلاَّ إِيَّاهُ)[2]

Табигатькә табынучыларның, чынлыкта, мәгъбүдләре Ходадыр. Илаһилеккә игътикад иткәннән соң сәҗдә итсәләр, мәсҗүд[3], чынлыкта, Хода улур. Табигатькә табынучылар нисбәттә никадәр ялгышсалар да, касыдларында, әлбәттә, дөреслеккә ирешәләр.

Ислам шәригате табигатькә табынучыларның максатларына ирешүләрен игътибар һәм ихтирам итеп, ул өч вакытта сәҗдә кыйлуны табигатькә табынучыларга хаслаган булса кирәк.

Аңлатма шундый булса, көфер галәмәте иман галәмәтен җиңгән булып чыкмаячак, бәлки иман үзе гүзәл бер өстенлек кәсеб иткән булыр. Мәгъбүдиятнең, мәсҗүдлекнең бары тик бер Аллаһ Раббел-галәмин хәзрәтләренә хаслануы да гаять гүзәл сурәттә расланыр. «Ислам шәригате сәмави диннәрнең һәрбере белән ихтирам нигезендә мөгамәлә итә» дигән кагыйдә дә дәлилләнгән булыр.

Җир йөзендә бар булган һәммә нигъмәтләрнең, кеше файдаларына, хаҗәтләренә сарыф кыйлына торган һәммә игелек-

---

[1] икърар – тынычландыру, икърар итү, тану.

[2] «Һәм синең Раббың үзеннән башка һичкемгә дә гыйбадәт кылмавыгызны икърар кыйлды» (Коръән, 17:23).

[3] мәсҗүд – үзенә сәҗдә ителүче.

нең, галәмне яктыртып торган нурның чыганагы кебек күренгән кояшны табигать этәрүе белән кешенең олылавы кебек үзенчәлеккә беркадәр хакыйкыйлык төсе бирү кәламчыларның карашына күрә диннең нигезе булган (شكر المنجم واجب عقلا)[1] кагыйдәсенә дә тулысынча туры килә.

«Вөҗүдме, һәммә хаҗәтләрме, һәммә игелекне миңа биргән улдыр», дигән инану белән табигатькә гыйбадәт кыйлучы кояшка гыйбадәт итсә, ялгышуы максатында түгел, нигъмәтләндерүчегә шөкер итүендә түгел, бәлки чыганакны тәгайен итүе хосусындадыр. Хакыйкый нигъмәтләндерүче кояшның Халикы икән, кояшны нигъмәтләндерүче дип гөман итү ялгышу булыр, җитешсезлек булыр, ләкин ишракь[2] булмас. Хакыйкый нигъмәтләндерүчедер дигән инануы белән күренеп торган нигъмәтләндерүчегә гыйбадәт итүдә дөреслек төсмере, әлбәттә, бар. Табигатькә гыйбадәт итүче, чынлыкта, Ходайга гыйбадәт итә.

Исламиятнең башка диннәргә нисбәттән югарылыгы, миңа калса, бу җиһәте белән тагын да яхшырак күренә. Исламият кешеләрнең фикерләрен, хис-тойгыларын күренеп торган нәрсәләрдә биклэп тотмый. Бәлки хакыйкатькә юл күрсәтә. Никадәр бөек булса да, кояш кебек, кайбер нәрсәләргә чыганак булса да, мәхлукъ хозурында хурлыкка калудан, түбәнчелектән кешеләрне саклый, кеше булу дәрәҗәсен югары тота, чиге булмаган галәме вөҗүднең зәррәләре булган йолдызларга, кояшларга илаһилек сыйфаты бирү кебек тарлыктан, караңгылыктан, җитешсезлектән кеше акылын азат итә. Илаһияткә инануларында кимчелекләре булган кешеләрне, ташламалар юлы белән хакыйкатькә туры юл күрсәтү аша, дәгъвәт идәр.

***

Батмаган кояшны тамаша кыйлган минутларда минем акылымда шундый фикерләр, калебемдә шундый хисләр акты.

[1] тәрҗемәсе: «игелек кыйлучыга шөкер кылу акыл күзлегеннән караганда мәҗбүридер».

[2] ишракь – ширек кылу; ширек.

Барлык кадәр киң, күкләр кадәр бөек исламият шәрәфе белән йөрәгебездә, күзебездә булган «югарылык» хисе белән без батмаган кояшны бер сәгать кадәр тамаша иттектән соң таудан төштек. Балаларның аяк тибешләре белән тәгәрәп киткән кечкенә туп кебек, кызган-кызарган ут тубы кебек, кояш офык буйлап тәгәрәп бара иде. Ниһаяте юк галәме вөҗүдне башлап җибәргән Халикъның газаматы михрабында кояш белән бәрабәр мәңгелек сурәттә сәҗдә кыйлу шәрәфенә ирештек. Шаригъ хәким теле белән фарыз кыйлынган намазларның вакытларын эзләү мәшәкатьләреннән, таба алмау гафиллекләреннән котылуыбызны күңелебез белән күрдек. Сәяхәтебездән килгән гыйльми һәм дини файдаларга шатланып кайтып киттек.

# Әдәбиятыбызның киләчәге[1]

Шаулый диңгез, җил өрәдер,
Җилкәнен киргән кораб
Төн вә көндез ул йөрәдер,
Юл бара ят ил карап.
Чыкты җилләр, купты дулкын,
Ил корабын җил сөрә,
Кайсы юллар, нинди упкын
Тарта безне җан сорап.

*Дәрдмәнд*

Мөхтәрәм шагыйребез Дәрдмәнд хәзрәтләренең бу дүрт бәете – Русия мөселманнары шагыйрьләренең, бәлки гомүм төрек шагыйрьләренең тел бәлягатьләре[2] белән бүгенгә кадәр әйтелә алган гүзәл шигырьләрнең дә иң гүзәледер.

Безнең бүгенге иҗтимагый әхвәлебезне, әдәби әхвәлебезне игътибарлы сурәттә тәхлил итеп[3], ерактан күрә торган күз белән киләчәгебезгә озак вакыт караганнан соң, Дәрдмәнд хәзрәтләре дәһшәтләнгән күңеле белән, өметсезлек теле белән ул көчле тәэсир итә торган бәетләрне әйткән булса кирәк.

Бүгенге хәлебезне, һәм дә бу хәлебезнең нәтиҗәсендә килә алачак дәһшәтле киләчәгебезне бу дүрт бәеттән дә ачык, бу дүрт бәеттән дә тулы рәвештә тасвир итә алган сүз телебездә юк булса кирәк. Ләкин бу дүрт бәеттән өметсезлек карашы аңланмаса иде, күңелләребезгә бу шигырьнең тәэсире тагын да матур, тагын да куәтле булыр иде. Өметебезне өзмәк, җаныбызны измәк урынына, рухыбызга – куәт, йөрәгебезгә – өмет, барлыгыбызга җан бирер иде.

[1] Чыганак: Муса әфәнде Бигиев. Халык назарына берничә мәсьәлә. Казан: Электро-Типография «Умид», 1912. Б. 14–33. (Өзек татар теленә тәрҗемә ителде).

[2] тел бәлягате – телнең үтемлелеге, тәэсирлелеге, риторик камиллеге.

[3] тәхлил итеп – күзәтеп, анализлап.

Бүгенге хәлебездән Дәрдмәнд шагыйрьнең тәэсиренә күрә, хәят диңгезендә мәдәният хәлләренең көчләве белән җилкәннәрен киереп хәрәкәткә әзерләнгән ил корабы – үз куәте белән, үз идарәсе белән түгел, бәлки һәр тарафтан уйнар давыл-ураган куәте белән, дәһшәтле дулкыннар арасында мәгълүм булмаган юллардан ят илләргә карап сөрелмәктә, харап итә торган упкыннар авызына ихтыярсыз тартылмактадыр.

Дәрдмәнд шагыйрьнең дәһшәтле тәэсире, бу дөрес сүзләрне безнең бүгенге хәрәкәтебезнең киләчәктәге нәтиҗәләрен күзаллап әйтелгән булса кирәк. Юкса, «кайсы юллар, нинди упкын тарта безне җан сорап» димәс иде. Чөнки әүвәлге хәрәкәтләрнең юллары, аларның һәммәбезне харап иткән упкыннары безгә дә, Дәрдмәнд хәзрәтләренә дә һәммә тәфсиләте белән мәгълүмдер.

Әүвәлге хәрәкәтләрнең юллары, упкыннары хакында бередә бер-ике сүз әйтмәк артык булмаса кирәк.

Шаригъ кәрим сәййид әл-вөҗүд, галәйһи-с-саләт вә-с-сәлам, хәзрәтләренең[1] арадашлыгы белән кешеләргә өйрәтелгән исламият ул гүзәл иҗтимагый шәригать, гаять матур гамәли шәригать буларак тормышка ашырылган иде. Ягъни, кеше тормышын ислах[2] кыйлу, һәйәт иҗтимагыя[3] хәлләрен тәртипкә китерү юлында гамәл кыйлу – исламиятнең иң мөһим максаты иде. Шуңа күрә, Коръән кәрим һәйәт иҗтимагыя нигезләрен никадәр зур игътибар белән бәян иткән булса, мәдәни мөгамәләләрнең вак өлешләрен дә шул кадәр зур игътибар белән бәян итмештер.

Җәмгыятьнең гомуми асыл вә нигезләрен, кечкенә элементларын гаделлек, мәнфәгать вә мәслихәт нигезләре өстенә бина кыйла алган гамәл – исламияттә, һәрхәлдә, иң мөһим максат иде.

---

[1] Шаригъ кәрим сәййид әл-вөҗүд галәйһи-с-саләт вә-с-сәлам хәзрәтләре – Мөхәммәт пәйгамбәр (ﷺ) хәзрәтләре.

[2] ислах – яхшыга таба үзгәртү, яхшырту.

[3] һәйәт иҗтимагыя – иҗтимагый система.

Мәдәнияттән, игелеклелектән бик ерак булган бәдәвият галәме[1] исламият рухы белән берничә ел тәрбия кыйлынганнан соң, иң әүвәл үзләренең хәлләрен яхшыртулары, аннары башка дәүләтләрне үзләренә кыска бер вакыт эчендә буйсындырулары безнең бу дәгъвабызга гаять гүзәл шаһит була булса кирәк.

Игелеклелек белән хәерле гамәл дәвам иткән вакытта исламиятнең куәте һаман арта барды, ул вакыт галәме мәдәнияттә[2] иң зур җитәкчелек, иң зур идарә исламият кулында иде. Әгәр дә ул вакытта исламият галәмендә исламиятне гыйлемнән аерган бер бәла барлыкка килмәсә иде, исламиятнең куәте, җитәкче булуы һаман артыр иде. Бүген җир йөзенең үзе дә, харитасы[3] да тәмам башка бер төстә булыр иде.

Ләкин галәме исламияттә гамәл һәм эшлеклелек рухы озак яшәмәде: фарсы мәдәнияте арадашлыгы белән оятсызлык, бозыклык, кәеф-сафа, ялкаулык чирләре хөкүмәт даирәләренә, байлар катламына тамыр җәйде. Ислам дәүләтләренең золым юлы белән тупланган бар кадәр мал-капиталлары дәүләт мәнфәгатьләренә түгел, бәлки хөкүмәт даирәләренең бозыклыкларына тузгытыла иде.

Моннан соң исламият галәмендә тагын да зур бер фетнә чыкмаган булса иде, бары тик ул дәһшәтле чирләр исламиятнең барлыгын, ихтимал, харап итә алмас иде. Чөнки гамәл һәм эшлеклелек куәте белән җир йөзенең һәммә хәзинәләрен кулда тота алган дәүләт хөкүмәт даирәләренең чиксез оятсызлыкларын, бәлки, күтәрә дә алыр иде.

Илаһи кадер куәте белән баш күтәргән фетнә уянды: бары тик теория-назарияттән, уйдырмалардан гыйбарәт булган

---

[1] бәдәвият галәме – биредә чүлләрдә күчмә тормыш кичергән гарәп кабиләләре күздә тотыла.

[2] галәме мәдәният (мәдәният дөньясы) – әлеге төшенчәне биредә кулланганда М. Бигиев мәдәнилек дәрәҗәсенә ирешкән борынгы цивилизацияләр турында, шул исәптән ислам дәверенә кадәр яшәп килгән илләр турында да сүз йөртә.

[3] харита – гарәп теленнән татар һәм урыс телләренә үтеп кергән бу сүз карта (географик карта, сәяси карта) буларак кулланыла.

юнан фәлсәфәсе[1] гарәп теленә тәрҗемә ителде. Нәтиҗәдә, исламиятнең һәм йөрәге, һәм мие иң үтергеч агу белән зәһәрләнде. Исламиятнең һәммә голүме, һәммә гамәле матди бер тиенлек файдасы булмаган буш теория даирәләренә кертелеп ябылды.

Исламиятнең иҗтимагый шәригате, гамәли шәригате – гамәлдә әсәре дә булмаган бер назари-теоретик шәригать, фаразлардан гыйбарәт булган вә фаразлар белән эш итә торган шәригать булу түбәнлекләренә төште. Исламиятнең саф һәм садә илаһи гакыйдәсе голүм кәламияләрнең җаһиллеге белән пычранды һәм үзгәртелеп бозылды.

Йөрәкләре дә, баш миләре дә теория белән, төрле каршылыклы фикерләр белән мәшгуль булып калган әһле ислам иҗтимагый, икътисади, мәдәни хәлләрне бөтенләй игътибарга алмый башларга мәҗбүр булды, санга сукмый башлады. Бу гамьсезлекнең этәрүе белән булса кирәк, әһле ислам галәме мәдәнияттә баш булу, җитәкчелек итү тәхетләрен башка милләтләргә калдырды да, нәтиҗәдә, әсирлек чылбырларын гүя үз куллары белән, үз ихтыяры белән үзенең муенына тагып куйды.

Галәме исламияттә әүвәлге гасырларда башланып киткән ул олы фетнә берничә гасыр дәвам итүе аркасында, бөтен галәме исламиятне, мәчетләрне, мәдрәсәләрне, йорт-ханәләрне, мәҗлесләрне тулысынча басып алды. Мәгънәсез, буш-биһүдә назарият эчендә бәхәс итә торган, моның өстенә барлык голүм вә фәннәрне инкяр итә торган кәлам китаплары ислам мәмләкәтләренең һәр кыйтгасында язылып, хөкүмәт куәте белән таратыла иде, халык даирәсендә пропагандалана иде.

Бүген без ул китапларны укысак, хәйран калачакбыз. Ул кадәр файдасыз нәрсәләрне язган каләм ияләренә, андый юкбар нәрсәләрне уйлаган акылларга, ул кадәр вак мәсьәләләр белән канәгатьләнгән галимнәргә, ул мәсьәләләрнең гомуми бербөтенлеген «ислам гакыйдәсе», дип, «исламча иман итү»

---

[1] юнан фәлсәфәсе – борынгы (антик) грек фәлсәфәсе.

дип атаган мөтәкәллимнәргә[1] без ул вакытта, әлбәттә, ихтирам күзе белән карый алмаячакбыз.

Бары тик Газали[2] кебек бөек имамның каләме белән язылган «Тәһафут»не[3], бары тик Ибне Рөшед[4] кебек гүзәл фәлсәфәченең каләме белән язылган «Тәһафут әт-Тәһафут»-не[5]. Әйтегез, зинһар, шушы ике китап кебек китаплардан кыйммәткә ия булган бер генә булса да сүз, бер генә булса да файдалы фикер алына аламы?

Күрегез, һәндәсә[6], һәйәт гыйлемнәрендә[7] югары дәрәҗәле белгеч булган Насыйретдин Тусыйның[8] каләме белән язылган

---

[1] мөтәкәллим – кәлам белән шөгыльләнүче кеше.

[2] Газали (Әбу Хәмид Мөхәммәд ибне Мөхәммәд әл-Газали әт-Туси, 1058–1111) – мәшһүр дин галиме, фәкыйһ, фикер иясе, фәлсәфәче, тәсаввыфчы (суфый). Суфыйчылыкка нигез салучы абруйлы галимнәрнең берсе булган, рәсми исламга суфыйчылыкны таныттырган, аларны килештерә алган практик.

[3] «Тәһафүт» (тулы исеме «Тәһафүт әл-фәласифә», ягъни «Фәлсәфәчеләрне кире кагу») – Газали хәзрәтләренең Көнбатышта танылган һәм ислам дөньясында эш иткән фәлсәфәчеләрнең карашларын тәнкыйтьләгән мәшһүр рисаләсе.

[4] Ибне Рөшед (Әбу әл-Вәлид Мөхәммәд ибне Әхмәд әл-Куртуби, 1126–1198) – гарәп фәлсәфәчесе, Аурупа фәнендә, фәлсәфәсендә Аверроэс буларак танылган галим, мантыйкчы, Аристотель тәгълиматын популярлаштыручы, ислам фәлсәфәчесе, дин белеме, фикъһы, география, математика, физика, астрономия, күк җисемнәре хәрәкәте, медицина, психология һәм сәясәт буенча күпсанлы хезмәтләр авторы.

[5] «Тәһафүту әт-тәһафүти» («Тәһафүт»не кире кагу») – Ибне Рөшеднең әл-Газали язган «Тәһафүту әл-фәласифә» исемле рисаләсенә каршы язылып, Аристотель тәгълиматын яклауга багышланган мәшһүр фәлсәфи рисаләсе.

[6] һәндәсә гыйлеме – сызым, геометрия, соңрак дәверләрдә инженерия, төзелеш мәгънәләрендә дә кулланыла башлаган фән исеме.

[7] һәйәт гыйлеме – күк җисемнәре хәрәкәтен өйрәнә торган фән, космология, астрономия.

[8] Насыйретдин Тусый (Насыйретдин Әбу Җәгъфәр Мөхәммәд ибне Мөхәммәд әт-Тусый, 1201–1275) – чыгышы белән Фарсыстан төркиләреннән булган математик (тригонометрияне астрономиядән

«Тәҗрид»[1] кебек китапларны; күрегез ул китапларга каршы чыгып яки аларны яклап язылган зур-зур калын китапларны, хисабы юк хәшияләрне[2], шәрехләрне[3]!

Исламият хакы өчен әйтегез, акыл сау булганда, күңел пакь булганда, андый саташуларны уйламак, сөйләмәк вә язмак мөмкинмедер?

Укыгыз «Мелла Җәлал»[4] кебек китапларда иң олы горурлык белән бәян ителгән «вөҗүһ хәмсә»[5]ләрне, укыгыз сый-

---

аерып махсус фәнгә әйләндергән), механик, астроном. Фәлсәфә, әхлак, география, музыка, оптика, медицина, минералогия буенча хезмәтләр авторы. Антик гыйлемнәрне, аерым алганда, борынгы юнан (грек) фәлсәфәсен яхшы белгән, Эвклид, Архимед, Автолик, Феодосий, Менелай, Аполлоний, Аристарх, Гипсикл, Птолемей әсәрләренә шәрехләр язган. Төрки, гарәп һәм фарсы телләрендә язган әсәрләренең саны 150дән ашып китә. 1256 елдан башлап Кубилай ханның киңәшчесе булып торган.

[1] «Тәҗрид» – М. Бигиев Насыйретдин әт-Тусыйның фәлсәфи кәлам әдәбиятының беренче үрнәкләреннән булган «Тәҗрид әл-игътикад» («Тәҗрид әл-кәлам» буларак та танылган) исемле әсәрне күздә тота. Бу әсәрендә әт-Тусый шигыйлыкның, шигый дин фикере, шигыйлыкның дини нигезләре турында тулы мәгълүмат биргән.

[2] хәшия – техник төшенчә буларак китап яки кулъязма кырларында язылган өстәмәләр һәм аңлатмалар; фәнни мәгънәдә берәүнең нинди дә булса дини әсәргә карата язылган аңлатма-комментариена, ягъни шәрехенә башка берәү тарафыннан язылган өстәмә аңлатмалар хәшия дип атала.

[3] шәрех – аңлатма, комментарий; шәрех дип нинди дә булса авторның дини әсәренә карата башка берәү тарафыннан язылган аңлатма-комментарийлардан гыйбарәт булган яңа әсәр атала. Коръәнгә караган шәрехләр тәфсир яки тәэвил дип аталалар. Әлеге ике термин бары тик Коръәнгә карата кулланыла, шуңа күрә кешеләр тарафыннан иҗат ителгән әсәрләргә язылган аңлатмаларны тәфсир яки тәэвил дип атарга ярамый.

[4] «Мелла Җәлал» («Җәлал мулла») – Сәгъдетдин әт-Тәфтәзанинең (1322–1390) «Тәзһиб әл-мантыйк» («Мантыйк (логика) сабагы») исемле китабына Җәлалетдин әд-Дәввани (1426–1502) тарафыннан язылган шәрехнамә (аңлатма).

[5] «Вөҗүһ хәмсә» (хакыйкатьне танып белүнең биш ысулы) – кәлам фәлсәфәсенең бәхәс үзәгендә торган мәсьәләләрнең берсе.

фат[1], әфгал-е Аллаһ[2], халк-ы әфгаль[3] кебек мәсьәләләрдә әшгарилар[4] каләме белән язылган сүзләрне, укыгыз шигыйлек-сөннилек каршылыклары турында оят-хәяне белмичә әйтелгән мыскыллауларны, әдәпсезлекләрне! Боларның соңында, мөкаддәс дин хакына, әйтегез: бармыдыр ул нәрсәләрнең җенләнүдән, ахмаклыктан аермалары?

Тәфтазани гасырыннан соң Төркестан, Һиндыстан, Иран, Төркия, Гарәпстан, Русия мәдрәсәләрен саранча чикерткәсе кебек сарып алган хәшияләрне, шәрехләрне, гомумән фикъһы, кәлам, мантыйк, усуль[5], тәфсир, нәхү, сарыф, хикмәт китапларына кагылышлы сурәттә язылган хәшияләрне, шәрехләрне күрегез дә, әйтегез, ул китапларда акылдан, фикердән, исламияттән бер генә булса да эз бармы?

Шул унбиш-егерме юлда күрсәтелгән сәбәпләрнең һәрбере үз башына исламиятнең шәүкәтнең[6], куәтнең, гыйззәтнең[7] мәхрум булуына мөстәкыйль сәбәп була ала. Ул сәбәпләрнең уртак тәэсире белән әһле ислам торгынлыкка тарыды, тоткын булды, бөтен ислам галәме һәр җирдә һәр яктан башка

[1] сыйфат (биредә Аллаһының сыйфатлары мәгънәсен белдерә) – кәлам фәлсәфәсенең бәхәс үзәгендә торган мәсьәләләрнең берсе. Аллаһның нинди сыйфатларга ия булуы яки булмавы, ул сыйфатларның асыл табигате турындагы фикерләр кызу бәхәсләр уяткан булган.

[2] әфгал-е Аллаһ (Аллаһның кыйлганнары) – кәлам фәлсәфәсенең бәхәс үзәгендә торган мәсьәләләрнең берсе.

[3] халк-ы әфгаль (гамәлләрнең барлыкка китерелүе) – кәлам фәлсәфәсенең фигыльләрнең, ягъни гамәл вә хәрәкәтләрнең ятылышы турындагы бәхәс үзәгендә торган мәсьәләләрнең берсе.

[4] әшгариләр – кәлам фәлсәфәсенең иң киң таралган мәзһәбе иярченнәренең уртак исеме. Әлеге мәзһәбкә нигез салучы булып әл-Әшгари (Әбу әл-Хәсән Гали ибне Исмәгыйл әл-Әшгари, 873–936) тора.

[5] усуль (биредә: усуль әл-фикъһы, ягъни «фикъһының нигезләре, тамырлары» мәгънәсендә килә) – фикъһының (гомумән алганда ислам шәригатенең) чыганаклары, ислам хокукының теоретик һәм методологик нигезләре турындагы фән.

[6] шәүкәт – көч, куәт, гайрәт.

[7] гыйззәт – дан, шөһрәт, абруй, горурлык.

милләтләрнең кулларында әсир кебек калды. Ул сәбәпләрнең үтергеч нәтиҗәләре бары тик болар гына түгел иде, алар мөселманнарны исламияттән, шәригать исламиядән, пәйгамбәрнең сөннәтеннән мәхрум иттеләр.

Нәтиҗәдә, дини мәдрәсәләребездә исламияттән бер әсәр[1] дә калмады. Белем алу дәверләре егерме-утыз ел кадәр дәвам итә торган Төркестан, Һиндыстан мәдрәсәләрендә, ун-унбиш ел кадәр дәвам итә торган Төркия, Гарәпстан җамигъларында[2] сарыф, нәхү, мантыйк, кәлам, хикмәт, фикъһы хәшияләре, китап дибаҗалары[3] укымактан, һәм дә булган кадәр сәламәтлекне, булган кадәр гүзәл әхлакны бозмактан башка һичбер нәрсә юк иде.

Төркестан якларыннан, Бохара мәдрәсәләре кебек иң җимерек бер чыганактан безгә үтеп кергән ул көчле чир безнең дини мәдрәсәләребездә тагын да көчлерәк вә яманрак бер рәвештә дәвам итте. Чөнки дәрес ысуллары һаман да шул иске ысул булса да, шәкертләрнең яшәеш ысуллары әхлак бозылуына тагын да киңрәк юл ача торган бер хәлдә иде.

Дини мәдрәсәләр барлык галәме исламияттә шундый яман хәлдә иделәр. Исламият минбәрләре дә моннан яхшырак хәлдә түгел иде. Асылда, күңелләргә рух бирмәк, динне, әдәп-әхлакны, Коръәнне өйрәтмәк вазифасы белән тәгаен кыйлын-

---

[1] әсәр (күплектә: әсар) – бу сүз асылда эз, билге, тамга дигән мәгънәләргә ия. Бу йөздән Р. Фәхретдиннең «Асар» дип аталган танылган биографик энциклопедиясенең татарча исеме «Эзләр» булыр иде. Бу сүз татар телендә нинди дә булса мәдәни ясалманы белдерә, мәсәлән, язучының әсәре; әдәби әсәр һ.б.ш.

[2] җамигъ – мәчет, ягъни мөселманнарның намаз укыр өчен җыела торган урыннары. Сәҗдә кыла торган урынны (ягъни, гарәпчә мәсҗид) белдергән мәчет сүзенең синонимы. Әмма аермасы да бар: татарча мәчет һәм җәмигъ мәчет төшенчәләре кулланыла, ә төрек телендә болар cami (җами, ягъни нинди дә булса мәчет) һәм mescid (месҗид, җәмигъ мәчет) буларак кабул ителгән.

[3] китап дибаҗасы – бирედә дини әсәрләргә язылган кереш сүз, мөкаддимәләр күздә тотыла.

ган[1] минбәрләрнең өммәт исламияне иң гафил[2] бер өммәт итмәктән башка файдалары, хезмәтләре юк иде.

Диннең мөкаддәс ике хәрәме[3] – мәдрәсәләре, җамигълары – шундый иде.

Ул хәрәмнәргә карата мәхәббәт иткән, ышаныч баглаган әһле ислам шул ике хәрәмдә үзләштергән тәрбияләре аркасында булса кирәк, һәрнәрсәдән: һәм диннән, һәм дөньядан мәхрүм калды.

Әһле исламның бүгенге мескенлекләрен, һәр җирдә әсирлеген истихсан итмәгән[4] һәрбер кеше – исламияткә мәхәббәт, әһле исламны ихтирам юлы белән әйтелгән бу сүзләрне арттыру дип санамас булса кирәк. Галәме исламның бүгенге мескенлекләрен, әсирлекләрен исламиятнең үзе белән берләштермәгән һәрбер мөселман безнең бу фикерләребезне, хөкемнәребезне кабул итә ала булса кирәк. Ислам дәүләтләренең тарихларына игътибар белән баккан һәрбер кеше – тарих сәхифәләренең һәрберсендә безнең сүзләребезнең дөреслеген раслый торган шаһитлар күрә булса кирәк. Исламиятнең һәм әһле исламның киләчәкләреннән өмет өзмәгән һәрбер мөслим – исламиятнең тарихына, киләчәгенә бу караш ноктасыннан шундый бер бинокль белән карый булса кирәк.

Мин бу карашымны китабым сәхифәләрендә бәян иткәндә бүгенге хәлебезнең сәясәтчеләр каләме белән язылган-күрсәтелгән сәбәпләрдән гафил түгел идем. Сәясәт белгечләренең каләме белән күрсәтелгән сәбәпләр югарыда бәян ителгән сәбәпләрнең, минем карашымда, ботаклары гынадыр. Әгәр

[1] тәгаен кыйлынган – булдырылган, оештырылган.

[2] гафил – гамьсез. Биредә надан, белемсез мәгънәсендә.

[3] хәрәм – изге урын, тыюлык. Әлеге сүз урыс теленә храм буларак үтеп кергән. Мәсәлән, Мәккәдә урнашкан изге Кәгъбә һәм аның әйләнәсендә гыйбадәт кыйлу өчен төзелгән корылмалар комплексы әл-Мәсҗид әл-Хәрәм дип атала, ягъни «Тыюлы мәчет». Ошбу хәрәм сүзен аның белән бер үк тамырдан ясалган хәрам сүзе белән бутамаска кирәк. Бу ике сүзнең мәгънәләре бик якын булса да, хәрам ул шәригать термины буларак тыелган, ясак булган нәрсәләрне, эшләргә ярамаган гамәлләрне белдерә.

[4] истихсан итмәгән – яхшы нәрсә дип танымаган, риза булмаган.

дә безнең күрсәттегебез сәбәпләр тиешле җирлек әзерләмәгән булсалар иде, юл ачмаган булсалар иде, сәясәтчеләр күрсәткән сәяси сәбәпләрнең үзе дә булмас иде.

Киләчәк сәхифәләрнең берсендә бу мәсьәләгә яңадан әйләнеп кайтырбыз бәлки, ә биредә «әдәбиятыбызның киләчәге» мәсьәләсендә сүзебезне дәвам итик.

Соңгы вакытларда галәме исламият гафләттән уянды, галәме исламияттә интибаһ[1] башланды димәк яраса, ул интибаһ, иң әүвәл, төрекләрдә башланды дип әйтү мөмкин булса кирәк. Ләкин ул интибаһ милләтнең уянуы түгел, бәлки хөкүмәтнең «уянуы» иде.

Төркия хөкүмәте милләт яшәешендә, дәүләт яшәешендә булган җитешсезлекләрне аңлады, аларны төзәтү-ислах чараларын эзли башлады, әмма уңышка ирешә алмады. Чөнки мәмләкәтнең үзендә эзләнергә-табылырга тиешле чараларны хөкүмәт тыштан, ятлардан эзләде.

---

[1] интибаһ – уяну.

Мәктәпләрне, дини мәдрәсәләрне, җамигъларны, шәргый мәхкәмәләрне[1], мәшийхәт исламияне[2], тәккәләрне[3], халыкта диянәтне[4] үз хәлләрендә калдырып, милләтнең иҗтимагый хәлләреннән, дәүләтнең икътисади хаҗәтләреннән тәмамы белән гафләт иткән кебек булып, хөкүмәт үзенең һәммә иҗтиһадын бары тик сәяси, гаскәри мәсьәләләргә багышлаган иде.

Милләттә сәвад[5] юк. Дини мәдрәсәләрдә диннең, гыйлемнең, акылның, әхлакның әсәре юк. Сүлпәнлеккә һәм гафиллеккә өйрәтә торган хатыйплар белән басып алынган минбәрләрдә рух юк. Җаһил залим хакимнәр[6] белән тулы мәхкәмәләрдә хокуктан, гаделлектән, хакыйкатьтән бер әсәр дә юк. Әһле исламны Көнбатыш сәясәтчеләренең мәгърифәте белән, я, булмаса, һаваланулары белән гамәлгә кертелә торган кануннардан, низамнардан саклап калырлык белем дә юк, көч

[1] шәргый мәхкәмәләре – шәригать судлары.

[2] мәшийхәт исламия (якынча тәрҗемәсе: ислам шәехләреннән, югары дәрәҗәле дин галимнәреннән гыйбарәт булган иҗтимагый институт) – әлеге атама I Сәлим (1512–1520) белән Сөләйман Кануни (1520–1566) исемле солтаннар хакимлек иткән дәвердә Госманлы дәүләтенең башкаласы булган Истанбул мөфтиләрен күздә тота. Искә алынган солтаннар дәверендә башкала мөфтие булуның динииҗтимагый әһәмияте артканнан арта башлый. Истанбул мөфтиенең дәрәҗәсе буенча дәүләттә икенче кешегә әверелү процессын Гали Җамали-әфәнде Зәмбилле (1501–1525) белән Әбу әс-Сөгуд-әфәнде (1545–1574) исемле мөфтиләр башлап җибәрәләр. Бу дәвердә шәйхелислам дип атала башлаган мөфтиләрнең вазифалары солтанның тышкы һәм эчке сәяси һәм иҗтимагый мәсьәләләргә кагылышлы фәрманнарын дини хөкемнәргә туры килүен күрсәтә торган фәтвалар чыгарудан гыйбарәт була. Алга таба шәйхелисламның ярдәмчеләре барлыкка килә, аларның саны арта башлый. Шуннан башлап Госманлы дәүләте хөкүмәте кысаларында эшләгән һәм мәшийхәт исламия, дип аталган мөстәкыйль ведомствоның барлыкка килүе турында сүз йөртеп була.

[3] тәккә – суфилар бергә яшәп, бергәлектә зикер-гыйбадәт кыла торган урыннары.

[4] диянәт – дин.

[5] сәвад – укый-яза белү, грамоталык, гомуми мәдәнилек, тәрбия.

[6] хаким – судья.

тә юк. Мәшийхәт исламия әгъзаларында көчәнә-көчәнә файдасыз «фәтвә»ләрне укудан башка бер һөнәр юк. Дәүләтнең һәммә чыгымнарын йөкләгән халыкның яшәеше, көнкүреше турында, икътисади әхвәлләре хакында фикер иткән адәм юк.

Ягъни, иң мөһим төзекләндерү-ислахат хакында хөкүмәт һичбер кайгыртуда булынмады, читтән алынган вак-төяк төзекләндерү «хәстә вөҗүд»[1] өстенә кирәксез бизәкләр тагу кебек калды. Вак-төяк ислахатның файдалары да зарарларыннан артык түгел иде. Чөнки Көнбатыштан алынган ислахат аркасында Гаребнең[2] бөтен яманлыгы, барлык бозыклыгы да килде.

Гаҗәмнән[3] калган оятсызлык белән Гаребтән аккан бозыклык берләшеп, халыкның вә милләтнең әхлакый-иҗтимагый хәлләрен тагын да ныграк бозды.

Бу гаять авыр сүзне исбат итеп тормыйм, бәлки исбат итәрлек осталык иясе дә түгелмен. Биредә бары тик бу кадәрен әйтә алам ки: Рум[4] белән Анадолу[5], Сүрия, Гыйрак кебек иң бәрәкәтле кыйтгалары булган матур җирләрне сәүдәдән, игенчелек-терлекчелектән, төзелештән тулаем рәвештә мәхрүм кыйлып харап иткән, башлангыч мәктәпләрнең хәлләренә һичбер вакыт игътибар итмичә, милләтне укый-яза белүдән тәмамы белән мәхрүм калдырган, моның белән бергә «хилафәт кубра исламия»не[6] коры дәгъва итүдән башка һичнинди сәяси адымнар, чаралар күрә алмаган хөкүмәт милләтне мәдәният юлларына кертеп җибәрә алды.

Ягъни, бары тик Истанбулда түгел, бәлки шәһәрләрнең, авылларның күбесендә каһвәханәләр, казинолар, кафе-шан-

---

[1] «хәстә вөҗүд» – чирле гәүдә.

[2] Гареб – Көнбатыш; Көнбатышның үсешкә ирешкән дәүләтләре; Көнбатыш цивилизациясе.

[3] Гаҗәм – борынгы Фарсыстан (хәзерге Иран).

[4] Рум – Византия империясе.

[5] Анадолу – Анатолия (хәзерге Төркиянең Азия тарафындагы биләмәләре).

[6] «хилафәт кубра исламия» – «исламның бөек хәлифәлеге».

теклерлар[1], кыйраәтханә[2] исеме бирелгән лафханәләр, лакырды клублары[3], бираханәләр[4] хөкүмәт әгъзалары һәм мәшийхәт исламия ярдәме белән ачылып, әүвәл дә нужа күреп яшәгән халык, шахмат, домино, карты, кәгазь-кумар[5] уеннарына, Аурупа исерткечләренә, төрле гайбәт вә имеш-мимеш турында гәпләшүләргә, нәтиҗәсе ызгыш-талаш була торган «мәхәббәт сөхбәтләре»нә тагын да күбрәк гадәтләнде. Хәтта бу «мәдәният» гаилә ханәләренә[6] кадәр үтеп керде.

Оятсызлыкның, бәталәтнең[7] бу кадәрендә тәкълид итү җитмәгән кебек, гаиләләрне, бәлки бөтен милләтне харап итә торган фәхешлек җиһәтләрендә дә халык Аурупага тәкълид итте. Һәм хөкүмәт, һәм мәшийхәт ярдәме белән фәхешханәләр, гомумханәләр[8], эреле-ваклы шәһәрләрнең һәрберсендә мәйдан яулап, канун химаясе белән булса кирәк, көн-төн ачыктан-ачык сурәттә хаҗиларны, изге урыннарны зиярәт кыйлу нияте белән юлаучыларны, мосафирларны дәгъвәт итә торган кадәр куәт һәм мәдәнилек кәсеп итте. Фәхешлеккә тагын да күбрәк үсеш бирү өчен булса кирәк, ятим балаларны, тол хатыннарны «каза вә кадер»[9] мәрхәмәтенә калдырган хөкүмәт фәхишәләрнең сәламәтлеген химая итә торган табиблар урдасын оештырды.

Оятсызлык капкаларының һәрбере аша халыкны Аурупага тәкълид иттерә алган хөкүмәт ияләре һәм мәшийхәт исла-

---

[1] кафе-шантеклер – клиентлар җәлеп итү өчен җырчылар җырлата торган кафе.

[2] кыйраәтханә – уку залы.

[3] лакырды – гәп, сафсата, лыгырдау.

[4] бираханә – сыраханә.

[5] кәгазь-кумар – акчага карта уйнау, гомумән отышлы уеннар.

[6] гаилә ханәләре – өйләр, шәхси даирә, гаиләләр.

[7] бәталәт – эшләмичә сорыкортларча яшәү.

[8] гомумханә – фәхешханә; зина йорты.

[9] каза вә кадер – кәлам фәлсәфәсенең, илаһи тәкъдир кысаларында адәм баласының ихтыяр иреге дәрәҗәсен бәхәс үзәгендә тота торган төшенчәсе. Әлеге төшенчә суфыйчылыкта да бар, әмма анда аның күзаллануы һәм асылы бөтенләй башка яссылыкта хәл ителә.

мия дәүләт карамагындагы мәктәпләр, голүм-фөнүннең һәр төре, һәр өлеше белән шөгыльләнә торган махсус институтлар, әдәби түгәрәкләр, фәнни мәҗлесләр, сәүдә ширкәтләре, сәнәгать[1] вә гамәл[2] төрлелегенә күрә төрле завод-фабрикалар кебек яшәешне һәм мәдәниятне үстерүче, рухландыручы нәрсәләр хосусларында, нидәндер, фикер кузгатмады, чаралар күрмәде. Казиноларга, кафе-шантеклерларга, исерткечләргә, фәхешлеккә ярдәм итеп милләтне харап булу юлларына кертеп җибәрә алган хөкүмәт һәм мәшийхәт исламия телеграф, телефон, тимер юллар, пароходлар кебек хәят һәм мәдәният тамырлары белән, сеңерләре белән ватанны төзекләндерү гамендә, кайгыртуда, нидәндер, булынмады.

Оятсызлыктан, фәхешлектән саклану, әхлакъ пакьлегенә, ватанның төзеклегенә, халыкның файдасы вә мәнфәгатенә хезмәт итә торган чаралар белән мәшгуль булу исламият әдәбенә, шәригать исламия рухына күбрәк туры килгәнен белә торып, милләт өчен оятсызлык капкаларын иң киң сурәттә ачкан хөкүмәт һәм мәшийхәт исламия нидәндер мәгариф, сәнәгать, гамәл, иҗтиһад кебек җитди хосусларда Аурупага тәкълид иттерү өчен тырышмадылар, кирәкле чаралар күрмәделәр.

Күңелләрне телгәләмичә уйлап яки тасвирлап булмаган бу хәлләрне бәян итүдән туктап калыйк. Үз әдәбиятыбызның киләчәге хакында бер фикер алмак, бер шаһит күрсәтмәк нияте белән, биредә Төркия әдәбиятына күз салыйк.

Әүвәл, госманлы әдәбиятында кабул ителгән тел мәсьәләсенә игътибар итик.

Төрекләрнең яңа әдәби әсәрләрендә тел күпчелек очракларда хаталы һәм зәгыйфь була. Хаталар җөмләләрнең дә һәм аерым сүзләрнең дә төзелешләренә хас. «Әдәби» исеме бирелгән телләрендә ясалмалылык, төссезлек гомуми бер

---

[1] сәнәгать – икътисадның мал җитештерү тармагы, технологияләр, промышленность.

[2] гамәл – биредә эшмәкәрлек, бизнес мәгънәсендә килә.

хәлдер. Борынгы каләм[1] белән язылып хәзерләнгән һәйәт[2], риязәт[3], тәшрих[4] кебек фәннәрнең телләрендә сыйххәт булса да, Аурупа әсәрләреннән яңа каләм белән тәрҗемә кыйлына торган яңа әдәбиятта һәр яктан матур һәм дөрес тел табып булмый. Кайчакта «Җиннәтнең әсбаб иҗтимагыясе»[5] исемле әсәрнең теле кебек тәмамы белән хата, төссез, ясалма була.

Телдә әһәмияте буенча иң беренче багана ул – аның дөреслегедер, ягъни аерым сүзләрнең, сүз вә җөмлә төзелешенең тел кагыйдәләренә тәмамы белән туры килүедер. Госманлы әдәбиятында тел дөреслеге тотрыклы күренеш түгел. Биредә сүз вә җөмлә төзелеше күпчелек очракларда гаҗәми, ягъни фарсыча, фарсы теле калыбына салынган була; аерым сүзләрендә хаталар еш очырый. Бо хосус[6], андый әсәрләр бары тик Аурупа тәрбиясе күреп, гарәбияттән[7], фарсияттән[8] хәбәре аз булган адәмнең каләме белән язылган язма, я теле белән сөйләнгән нотык булса.

Дөрес, телдә иң матур як – телнең аны ишетүчеләргә, укучыларга аңлаешлы булуыдыр. Җөмлә дөрес булмаса, ул җөмлә ни сүз, ни сөйләм була алмый. Җөмлә аңлашылмаса,

[1] борынгы каләм – биредә борынгы тел осталарының язма мирасы күздә тотыла.

[2] һәйәт – күк җисемнәре хәрәкәтен өйрәнә торган фән, космология.

[3] риязәт – математика.

[4] тәшрих – шәрех-хәшияләр язу.

[5] «Җиннәтнең әсбаб иҗтимагыясе» («Юләрлекнең иҗтимагый сәбәпләре») – мәшһүр француз галиме доктор Г.-Л. Дүпренең (G.-L. Duprat) «Les Causes Sociales de la Folie» исемле китабының 1912 елда Истанбулда төрекчә басылып чыккан тәрҗемәсе. Китапны төрек теленә Мәхмәт (Мөхәммәд) Фаикъ (Mehmet Faik Kaltakkıran, 1870–1948) тәрҗемә иткән.

[6] бо хосус – аеруча, хосусан, аерым алганда.

[7] гарәбият – гарәп теле вә әдәбияты һәм шулардан үсеп чыккан язма һәм сөйләм теле кагыйдәләре, традицияләре; гарәп тел белеме, филологиясе.

[8] фарсият – фарсы теле вә әдәбияты һәм шулардан үсеп чыккан язма һәм сөйләм теле кагыйдәләре, традицияләре; фарсы тел белеме, филологиясе.

андый җөмлә әдәби була алмый. Аңлаешлы булу әдәбилектә иң мөһим баганадыр.

Тел – гаҗәми[1] тәркибтән[2], ят кәлимәләрдән ни кадәр пакь булса, ул тел шул кадәр матур булыр, шул кадәр милли тел булыр. Милли телдә дөреслек, җиңеллек булса, менә шул тел әдәби тел булыр, бәлигъ[3] тел булыр.

Әдәбилектә бу өч багананы, ягъни дөреслекне, җиңеллекне, пакьлекне игътибарга алсак, госманлы әдәбиятнең әдәбилектән тәмамы белән мәхрүм булганлыгын күрәчәкбез. Теле халыкның гомуменә я, һич югында, күпчелегенә аңлашыла торган матур бер әсәр бүгенге госманлы әдәбиятында табыла алмый, андый бер әсәр юк. Болай булу гарәп һәм фарсы әдәбиятына сукырларча тәкълид кыйлуның нәтиҗәседер!

Төрекләрдә вәзенчеләр[4], бадигъчылар[5], гашыйклар, мәҗнүннәр[6], дәрвишләр[7] бар. Ләкин матур шагыйрьләр, ха-

[1] гаҗәми – тар мәгънәдә фарсыларга хас булган нәрсә; киң мәгънәдә – ят, башка халыкларныкы.

[2] тәркиб – тәртип, калып; төзелеш; структура.

[3] бәлигъ – үтемле, тәэсирле, төзелеше ягыннан камил.

[4] вәзенче (вәзен – үлчәү) – билгеле шигъри калыпларга (вәзеннәргә) туры китереп иҗат итә алучы шагыйрь яки грамматика һәм синтаксик өлгеләрне камил сурәттә кулланып яза торган чәчмә жанр остасы.

[5] бадигъчылар (кыскартылган гыйльм әл-бадигъ) – әдәби стилистика осталары, матур риторик сөйләм осталары, шигърият осталары.

[6] мәҗнүн (акылсыз, тиле; рус.: юродивый) – Аллаһ хакына, яки сөйгән яры хакына акылыннан ваз кичкән кеше. Асылда сүз җенләнү дип тәрҗемә ителергә тиеш, чөнки әлеге халәт кешенең җеннәр тәэсиренә буйсынудан гыйбарәт.

[7] дәрвиш (фарс.: ярлы, фәкыйрь) – Аллаһ белән кавышу өчен, аңлы рәвештә дөнья рәхәтләреннән ваз кичеп, хәерче халәтендә гомер кичерүне өстен күргән суфиларга карата кулланылган атама. Дәрвишләр арасында мосафирлар (торыр урыны булмаган, ягъни хәер эстәп көн күргән сукбайлар) һәм суфи ханәкәләрендә/тәкияләрдә яши торганнары булган. Дәрвишлек ислам мәдәниятенең үзенчәлекле һәм киң таралыш тапкан бер күренешен тәшкил итә. Казандагы Дербышки бистәсенең исеме дә Дәрвиш көйе, ягъни

лыкның хәлләрен, зәвыкларын, хиссиятләрен матур итеп тасвир иткән язучылар, укучыларына пакь зәвык, гүзәл хиссият бирә ала торган бөек әдипләр госманлы әдәбият дөньясында юк кебек. «Турфандамы турфамы»[1] кебек ике-өч әсәрне исәпкә алмасак, госманлы әдәбиятында матур бер нәрсә юк димәк мөмкиндер.

Госманлы әдәбиятта тел ягыннан булган җитешсезлекләр гаять күп вә зурдыр. Халыкныңголүмнән, мәгарифтән мәхрүм булуы, матбугатның гаять авыр хәрәкәте, халыкның әдәбиятка һәм әдәбиятның халыкка ят булуы кебек хәлләр – болар һәрбере телдән, телнең җитешсезлекләреннән үсеп чыга.

Без игътибарга аласы икенче нәрсә – ул госманлы әдәбиятында еш очрый торган романнар, риваятьләр мәсьәләсе.

Төркиядә бүгенге әдәбиятның иң зур өлеше күңел ачу өчен язылган хикәялардән, хыялый романнардан, гыйшык мөнәсәбәтләрен тасвирлаудан гыйбарәттер. Романнарның, хикәя вә риваятьләрнең күбесендә төрекләрнең милли тормышларына бер тиенлек мөнәсәбәте булмыйча, Аурупа тормышына, французларның оятсызлыкларына, фәхешлекләренә мөкиббән китү күренеп тора.

Тәрәккый[2] итеп мәдәниятнең гаять зур дәрәҗәләренә ирешкән Аурупаның хәзинәләрендә булган голүм, мәгариф, фәннәр, сәнәгать кебек җитди нәрсәләрне үзләштерү өчен бөтен тырышлыкларын сарыф итәргә тиеш булган чакта, җитдият дөньясыннан читкә атылган гыйшык романнарын, оятсызлык хикәяләрен тәрҗемә итмәк төрекләрнең ни сәяси,

---

Дәрвиш авылы (төрек.: köy) сүзтезмәсеннән ясалган.

[1] «Турфандамы турфамы» – Мәхмәт Морат-бәйнең (Мизанҗы Морат, 1854–1917) госманлы җәмгыятенең XIX йөздәге сәяси вә мәдәни яшәешен бәян итә торган эпик романы. Әсәр шул заманда барлыкка килгән әдәби әсәрләргә тәнкыйть рәвешендә язылган. Хәзерге заман төрек әдәбияты белгечләре әйтүенчә, әлеге китапта куелган мәсьәләләр ул заман өчен генә түгел, бүгенге көн өчен дә әһәмиятен югалтмаган.

[2] тәрәккый – җәмгыятьнең мәдәни-матди үсеше; прогресс.

ни дини-әхлакый, ни икътисади хәлләренә һичбер ягы белән туры килми иде.

Аурупа каләме белән язылган романнарның күбесе ялган гыйшык белән, яман гадәтләр белән тулы булып, мәдәният дөньясында булган бозыклыкны, вәхшилекне тасвирлый. Андый романнар гыйффәт[1] һәм әдәп кебек төшенчәләр даирәсеннән ерак торалар. Андый романнарның бере гүзәл каләм белән язылган булса да, бәянда булган сихер куәте белән, укучыларның акылларына күңелләренә тәэсир итә, матур әхлакны, бар кадәр әдәпне юкка чыгара, кешенең күңелендә хакыйкатьләргә карата саклана торган ихтирамны җимерә, кешенең күңеленә, фикеренә агу сеңдерә, кешедә сәламәт фикер, тугры караш, дөрес хөкем вә нәтиҗә чыгару калмый.

Әйе, Аурупа тәрәккый итте, ләкин романнары белән, риваятьләре белән түгел, бәлки сәүдәсе белән, җитди гамәлләре белән, сәнәгатьләре белән, гыйлемнәре белән, мәгарифе белән тәрәккый итте. Гыйшык турындагы романнарның, хыялый риваятьләрнең мәдәният хәрәкәтләренә киртә булудан, хәят пакьлегенә зыян бирүдән башка нәтиҗәләре, әлбәттә, юк иде.

Әүвәлге гасырларда ислам дөньясы үзенең яу чабу вә җиңүләре белән, сәясәте белән мәшгуль булганда, ислам әдәбияты иҗтимагый файдалар, кыюлык, җиңүләр, сугышларда яулап алынган маллар, атлар вә сугыш кораллары, кылычлар турында яза иде. Ул вакытта әһле исламның гомуми фикерләре, милли омтылышлары һәм максатлары шулардан гыйбарәт иде. Әмма соңрак дәверләрдә галәме исламияттә сәясәт итү, җиңүләргә ирешү читкә атылды. Ислам җәмгыятенең югары катлам вәкилләре арасында рәфаһиятькә[2] мөкиббән китү, оятсызлык, зәвыклылык белән мавыгу, кәеф-сафа кору, мул табыннар, туй-сыйлар әзерләү, дус-ишләр арасында гәп сатып вакыт үткәрү кебек бозыклыклар тарала башлады. Хосусый һәм гомуми мәҗлесләрдә сүз еш кына кызларга, угланларга, мәй вә шәрабләргә, җыр-биюгә кагылышлы була иде. Шуңа

---

[1] гыйффәт – сафлык, намуслылык; күңел вә тән пакьлеге.

[2] рәфаһиять – җайлылык; комфорт; муллык; иркен сулап яшәү.

күрә ул вакытның әдәбияты да мәй вә сөйгән яр, гүзәлләрнең буй-сыннары, чәч-зөлефе вә иреннәре турында яза иде.

Әдәбиятның иң гүзәл вазифасы да милләтнең фикерләренә, хәл-әхвәленә тәрҗеман[1] булмактыр, шуларны бәян итмәктер.

Ләкин француз романнарыннан, итальян җинаятьләреннән тәрҗемә юлы белән барлыкка килгән әдәбиятта милләтнең фикерләренә, милләтнең хәл-әхвәленә тәрҗеман була алу игелеклелеге, әлбәттә, булмый. Андый тәрҗемәләрдә бары тик үрнәк булу, өйрәтү, күнектерү куәте бар. Андый тәрҗемәләр Аурупада булган әхлакны, гадәтләрне, оятсызлыкны, җинаятьләрне укучыларның баш миләренә, күңелләренә сихерләү сыман бер рәвештә сеңдерә, садәлекне, пакьлекне, саулыкны боза, милләтне мәгънәви вә рухи яссылыкларда юкка чыгара. Башка телдән тәрҗемә кыйлына торган гыйшык романнарына, хыялый риваятьләргә минем карашым шушыдыр.

Мәдәният юлларына бездән байтак элек юнәлмеш төрекләрнең әдәби телләренә, романнарына кагылышлы карашымны яздым. Болай итүем үз әдәбиятыбызның киләчәге хакында берәр сүз әйтмәк дәгъвасы белән иде. Бүгенге әдәбиятыбызда, Гаяз-әфәнде Исхакый, Фатыйх-әфәнде Әмирхани кебек әдипләребезнең әсәрләрендә тел ягыннан дөреслек юктыр. Кулланылышта булган гарәби, фарси сүзләргә карата бары тик дошманлык фәлсәфәсе белән языла торган әсәрләребезнең телләре тагын да яман була. Караңгы адәмнәрнең һәрберсенә аңлаешлы итеп язу дәгъвасы белән языла торган фәнни язмаларның, сәяси мәкаләләрнең, дини әсәрләрнең телләре еш кына һәм ялгыш була, һәм аңлашылмас була. Гади сүзләребездә, һәм дә газеталарыбызның битләрендә кабул ителеп киткән тел күп очракларда урыслашкан тел булып чыга. Газета мәкаләләрендә, гади әңгәмәләрдә хаҗәт таләбе белән түгел, бәлки бары тик гадәт хөкеме белән инде рус сүзләрен байтак кулланабыз.

---

[1] тәрҗеман – биредә белдереп торучы, хәбәр итүче, чагылдыручы мәгънәсендә кулланылган.

Бүген әһәмияте әллә ни юк кебек күренә торган бу хәлнең ахыры яхшы булмаса кирәк.

Бу хәл телебезнең үзендә булган җитешсезлек түгел, бәлки әдипләребезнең каләмнәрендә, мөхәррирләребезнең карашларында булган бер игътибарсызлык, гамьсезлектер, бер илтифатсызлыктыр[1].

Әдәбиятыбызны җиңелләштерү дәгъвасы белән хата телне дә кабул итсәк, гарәби, фарси сүзләргә тик дошманлык фәлсәфәсендә булуыбыз сәбәпле һаман рус сүзләрен куллана башласак, һәммә тырышлыгыбыз киләчәк көннәрдә файдасыз булып чагачак.

Телнең җиңеллеге, садәлеге яхшы нәрсә, бәлки тиешле нәрсәдер, ләкин җиңеллек өчен хаталылык шарт түгелдер. Җиңел тел белән хата телне аермыйча, җиңел язу бәрабәренә хата язу кабул ителергә тиешле нәрсә түгел булса кирәк.

Караңгы булган һәр адәм аңлый алырлык кадәр җиңел булса, бәян һәм тел кагыйдәләренә һәр яклап тугры килә торган кадәр дөрес булса, менә андый тел әдәби тел була да инде.

Телнең әдәбилеген тәэмин итә торган иң мөһим багана икедер: 1) телнең җиңеллеге, 2) телнең дөреслеге.

Бу ике баганадан иң мөһиме дә – дөреслектер. Дөреслек нинди дә булса сүзнең ул сүзгә карата куелган шартларга туры килүе булса, җиңеллек – ул сүзнең бары тик бәлягатенә, ягъни кирәкле урында кирәкле сүз буларак кулланылуына шарттыр.

Телнең әдәбилеге гыйльми төшенчәләрне куллану, яки гарәби-фарси кебек ят сүзләрне кабул итеп алу мәгънәсендә түгелдер. Хаҗәт юк икән, ят сүзләрне кулланмак телнең ясалмалылыгына китерә, ят сүзләрне урынсыз алу һәм куллану зур хата була.

Минемчә, телнең иң зур әдәбилеге аның җиңеллеге белән дөреслегендәдер. Җиңеллек аерым сүзләрнең үзлеге белән яки сөйләм тезмәләренең матурлыгы, ягъни бәлягате белән

---

[1] илтифат – кызыксыну, кайгырту; ягымлылык күрсәтү; олылау, хөрмәт күрсәтү; игътибар күрсәтү; әһәмият бирү.

булыр. Иң бөек әдип – мәгънәсе матур булган, рухы бөек булган бер әсәрне иң җиңел, иң дөрес тел белән язган адәмдер.

Андый бөек әдипләрне һәм андый бөек әсәрләрне безнең әдәбиятыбыз галәме киләчәк көннәрнең берсендә бәлки күрә алыр, дип өмет итик. Ләкин тел дөреслеге, һәрхәлдә, иң зур шарттыр. Моның белән бергә, телебезнең садәлеге дә, ягъни ят сүзләрдән пакьлеге дә мөмкин кадәр таләп ителә торган нәрсәдер.

Кайбер мәгънәләрне белдерүдән тел яки каләм гаҗиз була ала. Андый вакытта гарәби, фарси, руси, фәрансави[1] кебек ят сүзләрне ала алабыз. Болай итү гаеп түгел, андый ихтыяҗ һәр телдә дә була. Зарары да, авырлыгы да юктыр, чөнки бүген ят булуы аркасында аңлашылмаган сүз иртәгә үз булыр да, аңлашылыр. Аерым сүзләрнең ятлыгы вакытлы бер авырлыктыр, киттекчә[2], ин шәа Аллаһ, ишәячәк монтазам мәктәпләребез[3] бәрәкәте белән, телебездә кабул ителгән гарәби, фарси кебек ят сүзләр үз малыбыз булыр. Ләкин бүгенге телебездә дөреслек булмаса, бүгенге әдәбиятыбыз киләчәк әдәбиятыбызга нигез булу мәртәбәсеннән, әлбәттә, мәхрүм калыр, бәлки читкә дә атылыр. Моның белән бергә, әдәбиятыбызга гаять көчле торгынлык бирер, киләчәк көннәрдә кыенлыклар тудырыр.

Бүген Русиядә нәшер ителә торган зур һәм кечкенә язмаларның күбесендә сүз һәм җөмлә хаталары азмы-күпме очрап тора. Болар каләм җитешсезлеге түгелдер, бәлки язучының бары тик бер игътибарсызлыгыдыр. Ләкин гаять матур телебезне һәм киләчәк әдәбиятыбызны ихтирам итү йөзеннән аларга карата игътибарлы булу, әлбәттә, тиештер.

Онытмыйк, Төрекстанның төрекләренең борынгы әсәрләрендә, һәм дә төрекләрнең бүгенге әсәрләрендә безнең телебез, сарыфы-нәхү кагыйдәләре белән бергә яхшы сурәттә

---

[1] фәрансави – францияле.

[2] *киттекчә* – тора-бара, вакыт узгач.

[3] монтазам мәктәпләребез (монтазам – уртак тәртипкә салынган) – уртак шәкелгә һәм таләпләргә туры китерелгән, барысы өчен дә бер булган уку-укыту программалары буенча эшли торган башлангыч һәм урта татар милли мәктәп челтәре күздә тотыла.

кәмалына ирешмәгән. Тырышлык ияләре булган башка милләтләр тау-таш асларыннан борынгы, үзләре өчен ят булган әсәрләрне чыгарып файдаланганда, үзебезнең мәдәни мәйданыбызда булган гүзәл әсәрләребезне санга сукмау безгә гаеп булса кирәк.

Бүгенге телебез – русның борынгы теле белән чагыштырыла алмый. Русның борынгы әсәрләрендә тел ягыннан җитешсезлекләр булса, бүген безнең телебездә дә андый җитешсезлекләрнең булуы шарт булмаса кирәк. Бүгенге әдәбиятыбызда булган җитешсезлекләрнең һәрбере вакытлы сурәттә гафу ителә ала, ләкин тел хаталары гафу кыйлына алмый булса кирәк.

Бүген нәшер кыйлына торган китапларның һәрберендә тел дөреслеге шарт ителсә яхшы булыр иде.

Башлангыч мәктәп китапларында тел дөреслеге, җиңеллеге, ят сүзләрдән мөмкин кадәр пакьлеге шарт ителергә, әлбәттә, тиештер. Китапның теле дөрес булмаса, ул китапны мәктәп програмына кабул итү рөхсәт ителергә тиеш түгел булса кирәк.

Әдәби телебездә дә, сөйләм телебездә дә, китап, хат, газеталарыбызда да ят сүзләрдән мөмкин кадәр пакьлек гүзәлдер, бәлки тиештер. Ләкин бу тиешлелек телнең дөреслегенә җинаять итмәү, аның сурәтләү вә фикерне җиткерү мөкинлекләренә зыян бирмәү, ясалмалылыкның булдырылмавы, гарәп вә фарсы телләреннән кергән сүзләргә бары тик дошманлык фәлсәфәсенә корылган мөнәсәбәттә булмау шартлары белән башкарылырга тиеш.

Башка телләрдән сүзләр алу зарурияте булмаганда, телнең ят сүзләрдән мөмкин кадәр пакь булуы таләп ителә. Ләкин һәр яклап үтәлгән вә кайгыртылган дөреслекне саклау иң беренче шарттыр.

Сүздән, язудан иң мөһим максат – аңлатудыр, фикер җиткерүдер. Әдәбилеге иң югары дәрәҗәдә булган тел ул – фикерне иң җиңел сурәттә бәян итә торган телдер. Әдәбилектә дөреслек – иң беренче шарттыр; җиңеллек, пакьлек – иң матур зиннәттер. Хаҗәт булмаганда ят сүзләрне алу, һәм кире-

сенчә, заруриять булганда, ят сүзләрдән саклану – боларның һәрбере ясалмалыктыр.

Әдәбиятыбызның теле мәсьәләсендә минем фикерем будыр: дөреслек, пакьлек, җиңеллек.

Тел мәсьәләсе соңында, әдәбиятыбызның эчтәлеге мәсьәләсенә килсәк, мәктәп китаплары, театр өчен язылган әсәрләр, гыйшык романнары хакындагы фикерем белән дә уртаклашыйм.

Тел дөреслеге шарт ителгәннән соң, мәктәп китапларының эчтәлегенә тагын да зуррак әһәмият бирмәк тиештер. Мәктәп балаларына иман, гыйльм-е халь, әхлак өйрәтү өчен язылган китапларның күбесендә, хәтта һәммәсендә азмы-күпме хаталар һәм мөнәсәбәтсезлекләр табыла.

Сабый балалар өчен язылган китапларда госелнең шартлары, хәез-нифас турындагы бүлекләрне, фарыз-ваҗиб арасындагы аермаларны, каза-кадер серләрен, халк-ы әфгаль[1] мәсьәләләрен, башка кәлами бәхәсләрне, ислам дәүләте, ягъни хилафәт[2] тәртипләрен, күздән вә акылдан яшерен булган нәрсәләргә кагылышлы игътикадның тәфсилләрен бәян итү һичбер сурәттә мөнасиб түгел[3] булса кирәк.

Мәктәп балаларына аталып язылган, сабыйларга тәкъдим ителәчәк әхлак китапларын вәгазь теле белән, мескенлек каләме белән, заһидлык фәлсәфәсе белән язу мөнасиб түгел булса кирәк.

«Тарих мөкаддәс»[4] китапларын «әнбияләр күндермәк[5], газап ирештермәк, кешеләрне харап итмәк, нәбиләрнең[6] китап-

---

[1] халк-ы әфгаль – фигыльләрнең, ягъни гамәл вә хәрәкәтләрнең яратылышы. Әлеге мәсьәлә кәлам китапларында бәхәс үзәгенә куела торган күпсанлы мәсьәләләрнең берсе.

[2] хилафәт – ислам дәүләтенең исеме.

[3] мөнасиб түгел – урынсыз, туры килми торган.

[4] «Тарих мөкаддәс» («Изге тарих») – исламияткә кадәр килеп киткән пәйгамбәрләр тарихы һәм сира, ягъни хәзрәт-и Мөхәммәднең (ﷺ) тормыш юлын тасвирлауга багышланган китаплар күздә тотыла.

[5] әнбияләр күндермәк – пәйгамбәрләр юллау.

[6] нәбиләр – пәйгамбәрләр.

ларын вә могъҗизаларын, яшәгән елларын санамак» ысулы белән язу – тарих мөкаддәстән хасыйл була алган файдаларны балаларга җиткерми булса кирәк. Бәлки, тарих мөкаддәсне, әхлак һәм дин тәгълимнәрен[1] өйрәтү өчен бер арадашчы итү, бөек нәбиләрне иҗтиһад, игелеклелек, истикамәт[2], әманәт, хикмәт үрнәкләре кебек күрсәтү, тарих мөкаддәс кыйссаларын балаларның рухларына, акылларына туры килгән рәвештә һәм яссылыкларда хезмәт иттермәк юлы белән язу – укыту ысулына да, тарих мөкаддәснең әхлакый максатына күбрәк туры килә булса кирәк…

Әдәбиятыбызда бүген булган, моннан соң да бәлки тагын да күбрәк булачак театр әсәрләре, гыйшык романнары хакында минем фикерем югарыда төрекләрнең романнарына, хикәяләренә кагылышлы рәвештә язылган юллардан күренде.

Динебезне, дөньябызны харап иткән әүвәлге халәтебездән киләчәк көннәребез өчен гыйбрәт дәресләре алып уянсак, бүгенге дини вә иҗтимагый хәлләребезгә кайгыртулы күз белән багып мәдәният юлларында мөмкин кадәр җитдилек белән хәрәкәтнең инде зарурилыгына тәмам инанган булсак, әдәбилек исеме бирелгән һәрбер әсәрне бары тик аңа хас булган иҗтимагый файдасы белән, ул файдаларының да җитдилеге белән, әһәмияте белән бәяләрбез, кадерен-кирәклелеген чамаларбыз.

Әдәби әсәр – безнең бүгенге хаҗәтләребезгә туры килә торган гүзәл һәм гамәли берәр файда бирә алса; гамәл, иҗтиһад, пакьлек, әманәт кебек иң җитди нәрсәләргә безне күндерә алса; тамырларыбызга төреклек каны, күңелләребезгә эшчәнлек җаны өрә алса; менә шундый бер әсәрнең кыйммәте, безнең карашыбызда, гаять зур булыр.

Юкса, рус романнарына тәкълид юлында язылу аркасында башка милләтләрнең олы хәстәлекләрен безгә йоктырудан башка «файдасы» булмаган әсәрләр; яки ялган мәхәббәт, бозык гыйшык агулары белән күңелләрне агулаудан башка

---

[1] тәгълим – укыту, өйрәтү; нәрсәне дә булса белем буларак үзләштертү.

[2] истикамәт – турылыклылык, тугры булу.

җимеш-сәмәрәсе булмаган романнар безнең бүгенге хаҗәтләребезгә туры килми булса кирәк, киләчәк көннәрдә таләп ителгән сәгадәтебезгә[1] дә юл ачмый булса кирәк.

Саф сөю, чын мәхәббәт, әлбәттә, мөкаддәстер, ул әгәр була алса, яхшыдыр, ләкин безгә мәгълүм бу мәдәният дөньясында мондый нәрсәләр гаять аздыр. Ялган мәхәббәт, бозык гыйшык исә оятсызлык капкасыдыр, әхлакый түбәнлеккә әйдәп баручы юлбашчыдыр.

Дөрес, әдәбият дөньясында гаять тәэсирле фаҗигаләр, бик матур тарихи романнар, бөек хисләр бирә ала торган әсәрләр табыла ала. Бәлигъ[2] каләм белән, гыйффәтле тел белән язылган булса, андый әдәбиятны уку азмы-күпме файда бирә ала. Ләкин бүгенге мәдәниятнең оятсызлыгы дөньясыннан алынган романнар, «Шантеклер»[3] кебек әкиятләр, «Күк кош»[4] кебек сай мәгънәле хикәяләр – безгә нисбәтән файдасыз нәрсәләрдер.

Үзенең «Шантеклер» кебек әкиятләренә, оятсызлык белән тулы романнарына бүгенге мәдәният дөньясы җенләнү дәрәҗәсендә әһәмият бирсә дә, безгә,ягъни исламият галәменә, төрки токым балаларына андый җенләнүләрнең, андый уеннарның һичбере туры килми булса кирәк. Мәгариф, сәнәгать, сәүдә-тиҗарәт, сәясәт кебек иң мөһим нигезләрне, табигатьтә булган һәммә хәзинәләрне үз кулына умырып ал-

[1] сәгадәт (бәхет) төрки телдә ырыс буларак яңгырый. Бу сүз борынгы төрки телебездә сакланган, ә татар телендә аның урынына фарсы теленнән кергән бәхет һәм гарәп теленнән кергән сәгадәт сүзләре кулланыла. Алтайда яшәүче җирле төрки телле, элек Алтай татарлары дип аталган халык хәзерге вакытта да бу ырыс сүзен куллана, мәсәлән, татарча «Хәерле юл!» – дигән теләк алтай телендә «Йолыгар ырысту болзын!» (ягъни «Юлыгыз бәхетле булсын!») – дип әйтелә.

[2] бәлигъ – үтемле, камил, төзек (сөйләм яки тел турында).

[3] «Шантеклер» – франк драматургы Эдмон Ростанның (1868–1918) 1910 елда дөнья күргән әкияти эчтәлекле сәхнә әсәре.

[4] «Күк кош» («Зәңгәр кош») – бельгияле драматург Нобель бүләге лауреаты (1911) Морис Метерлинкнең (1862–1949) 1908 елда язылган 6 пәрдәле әкияти эчтәлекле сәхнә әсәре.

ган Көнбатыш дөньясы берничә сәгатьләрен, берникадәр малларын үзенең әкиятләренә, юк-бар уеннарына сарыф итә алса да, мәдәниятнең иң мөһим нигезләрен һәм иң зарури хаҗәтләребезне читкә атып Көнбатышның бары тик уеннарына, бары тик кәеф-сафаларына алданмак безнең өчен гаеп булса кирәк.

Мәдәният дөньясы, ягъни Көнбатыш тәрәккый итте, дөрес. Ләкин юк-бар әкиятләр белән, оятсызлык һәм әдәпсезлекне сурәтләгән романнары белән түгел, бәлки үзенең мәгарифе белән, сәнәгатьләре белән, һәр хосуста гадәттән тыш иҗтиһады белән тәрәккый итте. Тәрәккыят юлларында үз башыбызга хәрәкәт итәргә кирәк дисәк, мәдәният дөньясына тәкълид итик. Ләкин бары тик кием-салым модаларында, мөгамәлә гадәтләрендә, ял итү, күнел ачуларда, оятсызлык төрләрендә, ашау-эчү ысулларында түгел, бәлки голүм, мәгариф, сәнәгать, сәүдә кебек җитди нәрсәләрдә тәкълид итик.

Аллаһның киң дөньясында бетмәс-төкәнмәс табигать шедеврлары бар икән, мәдәният дөньясында иге-чиге булмаган гыйлемнәр, мәгариф, сәнәгать әсәрләре бар икән, андагы оятсызлык турындагы, я гыйшык турындагы романнарын тәрҗемә итмәк, зифа буйны, күз-кашларны, асылташларны, уен кичәләрен, мәхәббәт хикәяләрен бәян итә торган әсәрләр язу безнең бүгенге дини, иҗтимагый хаҗәтләребезгә кагылышы, мөнәсәбәте булган хезмәт түгел булса кирәк.

Һәр нәрсәдән мәхрүм булуыбызны, мәдәният дөньясы каршында игътибарсыз булуыбызны һәрберебез таныйбыз. Ике-өч юллык мәкалә яза алсак, иң әүвәл милләтебезнең фәкыйрьлегеннән, түбәнлегеннән, наданлыгыннан матбугат сәхифәләрендә һәрберебез шикаять итәбез. Тануыбыз, шикаятебез дөрес булса, мәдәният дөньясында булган гыйлем, сәнәгать, фәннәр кебек иң мөһим хаҗәтләребез белән шөгыльләнмичә торып, оятсызлык дөньясында булган гыйшык романнары белән, мәхәббәт хикәяләре белән, уен кичәләре белән шөгыльләнмәк акыл кабул итә торган эш булмаса кирәк.

Без (ягъни исламият галәме) әүвәлге гасырларда сәясәт, риясәт иясе[1] булып, мәдәният юлбашчылары идек. Соңрак, юнан хорафатлары белән, кәлам җаһилиятләре белән шөгыльләнә башладык та, нәтиҗәдә, һәм диннән, һәм дөньядан мәхрүм калып, риясәт тәхетләреннән төштек, сәясәт мәйданнарыннан чыктык. Инде моннан соң, һәрнәрсәдән мәхрүм булганыбыз хәлдә, гыйшык романнары белән, мәхәббәт хикәяләре белән мавыксак, ялган вә уйдырма дөньясында калсак, шул ялган вә уйдырманың нәтиҗәсе мең мәртәбә яманрак булачак.

Әдәп-әхлакта, хәрәкәт-тотышларда, модаларда русларга, франкларга тәкълид итү мәртәбәсенә карата булган рәгъбәтебез[2] кебек, әдәбиятыбызда да русларга тәкълид итсәк, ягъни мөхтәрәм шагыйребез Дәрдмәнд хәзрәтләренең сүзе кебек «ят илләргә карап кичә-көндез юл китәр исәк», җилләр чыгар, дулкын кубар, ят илләрдә, дәһшәтле упкыннар арасында «ил корабыбыз» хәрап булыр.

Башка милләтләрнең хәятеннән алынган романнарны, оятсызлык дөньясыннан алынган хикәяләрне тәрҗемә кыйлып, «мәгыйшәт»[3] ысулларын, оятсызлык юлларын милләтебезгә сеңдерсәк, менә шул чакта кыска вакыт эчендә рухи сурәттә инкыйраз[4], һәм мәгънәви, һәм матди банкрутлык кичерәчәкбез! Андый романнар милләтне мәгънәви куәт[5] белән юкка чыгарачаклар.

Романнарның да гүзәлләре, ягъни әхлак һәм хисләрне тәрбия итә ала торганнары бәлки бардыр.

Романнарның теле дөрес, җиңел һәм пакь булса; бәян итү ысулы, эчтәлеге күңелләрне сихерләр кадәр тәэсирле һәм гыйффәтле булса; романда тасвирланган әхвәл милләтнең

[1] риясәт иясе – башлап эшләүче; башкаларга үрнәк булып алдан баручы, әйдәп баручы.

[2] рәгъбәт – көчле теләк; кызыксыну; омтылыш.

[3] мәгыйшәт – яшәеш, яшәү.

[4] инкыйраз – юкка чыгу, бетү. Биредә Муса Бигиев Гаяз Исхакыйның 1911 елда язылган «Ике йөз елдан соң инкыйраз» исемле романын күздә тота.

[5] мәгънәви куәт – рухи көч; идеологик көч; идеология көче.

хәятенә вә гореф-гадәтләренә тәмамы белән туры килсә; кешеләрнең рухи халәтләре иң дөрес, иң төгәл сурәттә ачылып күрсәтелеп, романнарның «каһарман»нары милләт балаларына иң матур рәвештә үрнәк була алса; андый романнар һәм әдәби, һәм тарихи яссылыклары белән файда китерә алыр. Андый романнар ләззәт белән укыла, кешенең күңеленә һәм акылына, аның табигатенә күрә тәэсир итсә дә, күпчелек очракларда тәрбия юлында, аны яхшырту юлында тәэсир итә. Мондый романнар, бәлки, бардыр да. Ләкин мин романнарның күбесе хакында карашымны бүгенге хаҗәтләребезнең таләбенә, бүгенге каләм ияләренең дәрәҗәсенә, тамырларыбызда аккан каныбызның халәтенә күрә яздым.

Дини, иҗтимагый хәлләребезгә игътибарлы күз белән карасак, башка милләтләр арасында бүгенге дәрәҗәбезне, кыйммәтебезне гаделлек үлчәве белән үлчи алсак, һәммә җитешсезлекләребезне, булган кадәр гаепләребезне тану күзе белән күргәннән соң ислах кирәклеген инде таныган булсак, һәммә хаҗәтләребезне таләп юлында җитдилек белән хәрәкәт итәчәк булсак, бөтен иҗтиһадларыбызны, һәммә куәтләребезне голүм, мәгариф, сәнәгать, сәүдә кебек бары тик җитди нәрсәләргә багышлавыбыз тиешле булыр. Әдәбиятыбызда да шулай. Табигать дөньясы турындагы фәннәр, төгәл фәннәр, иҗтимагый-гуманитар фәннәр кебек иң мөһим булган гыйлемнәргә кагылышлы әдәбиятыбызда бер китап та юк икән, мәктәп-мәдрәсәләрдә уку-укыту китаплары, дәреслекләр, гамәли кулланмалар тәртипкә салынмаган икән, «Таш кунак»лар, «Агач мулла»лар, «Карт хәзрәт»ләр, «Сөннәтче бабай»лар[1]… хаҗәтләребезнең таләбенә туры килми булса

[1] «Таш кунак» («Каменный гость») – А. С. Пушкинның сәхнә әсәре; «Сөннәтче бабай» – Гаяз Исхакыйның 1911 елда дөнья күргән әсәре; «Карт хәзрәт» – Тимерша Соловьевның (1875–1947) «Мужик илә мулла, яхуд Карт хәзрәт корган тозак» (Оренбург, 1902) исемле әсәренә ишарә булырга мөмкин. Телгә алынган «Агач мулла» исемле әсәр М. Бигиев тарафыннан аңлы рәвештә уйлап чыгарылган булырга мөмкин. Әлеге алым ярдәмендә галим ул замандагы әдәби әсәрләрнең әхлакый-эстетик һәм сәнгатьлелек яктан түбән дәрәҗәле булуларын ассызыклаган булса кирәк.

кирәк. Телләре дә дөрес булмаган андый китаплар телебезнең тәрәккыятенә хезмәт итми булса кирәк.

Бу сүзләремне базарда сатыла торган әсәрләргә карата шикаять юлы белән, яки андый әсәрләрнең таралу юлларын бағламак нияте белән язмадым. Базар булганда, анда, әлбәттә, һәр нәрсә булыр. Һәр адәм үзендә булган әзерлек куәте белән хәрәкәт итә. Беллетристләр хикәя, роман кебек әсәрләр язалар, филологлар борынгы заманда язылган әсәрләрне анализлау белән шөгыльләнәләр. Башка милләтләргә тәкълид кыйлу теләге безне дә ул юлларга, әлбәттә, тарта. Минем буш лафларым тәкълид куәте каршысында, беләмен, мәгънәсез һәм тәэсирсез кала. Һәр каләм иясенә табигый сурәттә хас булган хөррият җиһәтеннән чыгып хөкем итсәк, дөрес, шулай булыр. Ләкин бу очракта беренче урында халык хөкеменә чыгарылачак әсәрләрдә каләм иясенә табигый сурәттә хас булган хөррият булырга тиеш түгел, бәлки әсәрнең файдасы булырга тиеш беренче урында. Теле хата булган, рухы сай булган хикәяләрнең, уйдырма вә оятсызлык дөньясыннан алынган романнарның, әлбәттә, файдалары юк. Файдалары булса да, ул файдалар иң әүвәлге хаҗәтләребез җөмләсеннән түгелдер.

Безгә мәдәният дөньясында булган мәктәпләргә, институтларга дәвамлы сурәттә һөҗүм итеп, бүген мәгариф дөньясында булган һәммә голүмнәрне, һәммә фәннәрне өйрәттерү һәм үзләштертү – иң беренче һәм иң мөһим хаҗәттер. Әдәбиятыбызны да мәктәп китапларыннан башлап, зур уку йортларында, институтларда тәрбия күргән йөзләрчә, меңнәрчә булдыклы егетләрнең гүзәл каләмнәре белән язылган гыйлемнәр, фәннәр әдәбияты әзерләтү, ягъни андый егетләрне әзерләү заруридыр. Әһле исламның һәрберен гамәл һәм икътисад юлларына гадәтләндерү, актык кисәк икмәк өчен сакланган ике тиеннең берсен мәктәп юлында тотмак тиештер.

Бүгенге мәдәният мәйданнарында нәҗатыбыз[1] бары тик шушылар белән булыр.

[1] нәҗат (гарәп.: нәҗат – котылу) – ислами төшенчә буларак, Ахирәттә җәннәт әһле булу бәхетенә ирешү. Биредә мәдәнилек яссылыгында алгарыш, тәрәккый мәгънәсендә, торгынлыктан, наданлыктан, артта калганлыктан котылу мәгънәсендә килә.

Юкса, теле хата булган, рухы сай булган хикәяләрдән, кәеф-сафа һәм күңел ачу юлларын гүзәл сурәттә тасвирлый торган романнардан гыйбарәт булган әдәбиятыбызны баш итеп куйсак, мәдәни милләтләргә бары тик кием-салым модаларында, уен кичәләрендә тәкълид итсәк, әдәбиятыбызның да, киләчәгебезнең дә ахыры яман булыр.

Башка милләтләрнең тарихларында булып узган ялгышуларны кабатлау, мәдәни милләтләрдә булган хәлләрнең һәрберенә иярү тиеш булмаса кирәк.

Шөкер итик, безнең вөҗүдебез[1], йөрәгебез, баш миебез әле сәламәт. Күзебезне каплаган пәрдәләрне алып атсак, фикерләвебезне, акыл белән эш итүебезне комачаулап торучы киртәләрдән азат итә алсак, мәдәният юлларында пакь булып, сау-сәламәт булып хәрәкәт итә алырбыз.

---

[1] вөҗүд – биредә физик сәламәтлек, ныклык күздә тотыла.

# وَخَسَفَ الْقَمَرُ وَجُمِعَ الشَّمْسُ وَالْقَمَر [1]

Нөҗүм тәкъвимнәренең[2] хисабларына күрә, 1912 сәнә апрель 4 дә кояшның көсүфе[3] санияләре[4] мәгълүм иде. Март ахырларында Петербург җәридәләре[5] киләҗәк көсүфнең нәрәдә насыл[6] улачагына даъир мәгълүмат яздылар, тәфсыйлат вирделәр. Халка[7] шәкелендә улаҗак көсүфнең минтакасы[8] да тәгайен кыйлынды. Петербургда тамаша кыйлынаҗак көсүф халка шәкелендә улаҗак дәгел иде. Бән гомеремдә халка шәкелендә көсүфи күрмеш дәгелем. Уйлә бер көсүфнең тамашасына бән дә рагъбәт итдем[9]. Дөрест, гыйлеме һәндәсә[10] даъирәләрендә, нөҗүмнең дәкыйк[11] мәсьәләләрендә һәр фикер җәүлян[12] идәмәз исә дә[13], Аллаһның кодрәт илаһиясейлә[14] рәсем кыйлынмыш сәмаъ[15] даъирәләрендә, табигать хадисәләрендә[16]

[1] Чыганак: Муса Бигиев. Вә хасәфәл-камәру, вә җумига эш-шәмсү вәл-камәру // Шура. 1912. № 8. Б. 253–256. Мәкаләнең исеме Коръән айәтеннән гыйбарәт «…ай караңгы ителеп кояш белән ай бергә кушылгач…» (Коръән, 75:8–9).

[2] нөҗүм тәквимләре – планеталарның күк йөзендәге хәрәкәт юлларын күрсәтә торган таблицалар.

[3] көсүф – кояш тотылуы.

[4] сания – минут.

[5] җәридә – газета.

[6] нәрәдә насыл – кайда, ничек.

[7] халка – боҗра.

[8] минтака – урын.

[9] рагбәт итдем – нык теләдем.

[10] гыйлем-е һәндәсә – инженерлык; сызым, геометрия.

[11] дәкыйк – нечкәлек, нюанс.

[12] җәүлян – әйләнеп тору; хәрәкәт итеп тору.

[13] идәмәз исә дә – итә алмаса да.

[14] кодрәт илаһиясейлә – илаһи куәте белән.

[15] сәмаъ – күк, күк гөмбәзе.

[16] хадисә – вакыйга.

һәр фикер җәүлан идәр, һәр күз үзенә күрә күрер, назар идәр, ләззәт алур, йахуд гыйбрәт алур.

Петербургдан йөз илле чакрым мәсафәдә[1] «Серебрянка» стансиясенә апрель 4дә, сабах сәгать 9да хәрәкәт идәҗәк поезд ичүн бер һәфтә мөкаддәм[2] билет алуб куйдым. Көсүфнең һәммә дакыйкаларыны күрмәк ичүн лязем улаҗак әсбаби дә хазир итдем. Мөнәҗҗим[3] дәгелем, ләкин һәйәт гыйлеменә[4], Аллаһның галәмнәренә, табигать хадисәләренә рагъбәтем гаять бөекдер. Дөрест, хөсүф[5] көсүф хадисәләре гади хадисәләрдер, укадәр надир әл-вокуг[6] хадисәләрдән дәгелдер. Һәйәт китабларының бәянларына күрә һәр 18 сәнәдә (29) дәфга[7] хөсүф, (41) дәфга көсүф вакыйг улур[8]. Ләкин көсүфнең әксәре[9] йир йөзенең әксәрендә күренмәз, әмма хөсүфнең әксәре мөшаһәдә[10] кыйлынур.

Ләкин көлли көсүф[11] һәм халка шәкелендә күренүр көсүф – табигатьдә вокугы надир гариб[12] һәм җалиб[13] хадисәләрдәндер. Һәйәт әрбабы[14] уйлә хадисәләрдән гаять мөһим файдалар истихраҗ идәрләр[15]. Кояшның әхвәл табигыясе, камәрнең[16] әхвәл риязыясе[17] уйлә хадисә дакыйкаларында тәгайен кыйлынур.

---

[1] мәсафәдә – ераклыкта.
[2] бер һәфтә мөкаддәм – бер атна алдан.
[3] мөнәҗҗим – астроном.
[4] һәйәт гыйлеме – астрономия.
[5] хөсүф – ай тотылу.
[6] надир әл-вокуг – сирәк була торган.
[7] дәфга – тапкыр, мәртәбә.
[8] вакыйг улур – була.
[9] әксәре – күбесе.
[10] мөшаһәдә кыйлынур – күзәтелә.
[11] көлли көсүф – тулы кояш тотылуы.
[12] гариб – сәер, гаҗәп.
[13] җалиб – җәлеп итә торган.
[14] һәйәт әрбабы – астрономнар.
[15] истихраҗ идәрләр – чыгаралар; алалар.
[16] камәр – ай.
[17] әхвәл риязыясе – физик халәте.

Камәрнең җәсамәте[1], кутър мәхсүсе[2] шу көн(г)ә кадәр катгый сурәтдә тәгайен кыйлынмамыш. Нөҗүми хисабларда һаман беркадәр тәфавет[3] вакыйг улур. Камәрнең заһири кутърыны[4] рийазый сурәтдә галәл-катыг[5] тәгайен итмәк мәсьәләсе шу көнге мөнәҗҗимләр назарында гаять мөһим, гаять матлуб[6] бер мәсьәләдер. Көлли көсүф дакыйкалары, халка шәкелендә улур көсүф санияләре, камәрнең кутрыны хисаб ичүн иң бөек форсат кеби хисаб кыйлынур.

Буңа күрә, Петербург расады[7] апрель 4-дә вакыйг улаҗак көсүфи тамаша ичүн байтак йирләрә һәйәт гыйльмия күндерде. Хәтта Португалия мәмләкәтенә Бәхер Атласи сахиленә[8] ике мөнәҗҗими күндерүб куймыш иде. Зира[9] урада[10] апрель 4 көсүфе көлли улаҗак иде.

Апрель 4 килде. У көн чәһаршәнбә көне Петербургда күк йөзе ачык иде, һава гаять саф гаять гүзәл иде. Сабах сәгать 8дә ханәмдән чыкдым Варшавски вокзала йүнәлдем. Вокзал тәмамыйлә буш иде. 8 сәгать 50 дакыйкада махсус «Серебрянка» стансиясенә кидәҗәк поезд вагонларындан беренә биндем. Бәнем вагунда ике-өч рус мадамы вар иде. Әлләрендә[11] бинокль һәм йәшел кара пыялалар, моталәга ичүн[12] китаблар вар иде. Дигәр вагунда студентлар, кадетлардан гыйбарәт экскурсант таләбәләр дә вар иде.

Тәгайен кыйлынмыш дакыйкада поезд хәрәкәт итде. Петербургның җәнүб тарафына йүнәлдек. Өч сәгать имтида-

---

[1] җәсамәт – күк җисеме буларак үлчәме.

[2] кутър мәхсүсе – хис әгъзалары белән кабул ителерлек ягы; күзгә күренгән тарафы.

[3] тәфавет – аерма; үзгәлек.

[4] заһири кутърыны – күренә торган тарафын.

[5] галәл-катыг – катгый төстә.

[6] матлуб – таләп ителгән, кирәкле.

[7] расад – обсерватория.

[8] сахил – диңгез яры, диңгез буе.

[9] зира – чөнки.

[10] урада – анда.

[11] әл – кул.

[12] моталәга ичүн – уку өчен.

дында Серебрянка стансиясенә ирешдек. Петербургдан килмеш әтрафдан тупланмыш тамашачылар илә стансия тулу иде. Бәзем поездымызда килмеш җәмәгатьнең һәммәсе иңде. Бөек галәбәлек[1] эчендә стансия залларына кердек. Беренче класс буфеты бер мөселманның әлендә имеш. Беркач дакыйка карар соңында залдан чыкдык. Стансия йанында бөек һәм ачык мәйданда экскурсия һәйәтләре бүлек-бүлек улуб урунлашмышдыр. Әдәват расадияләрене[2] тәртиб итмешләр. Шу галәбәлеги дә бераз тамаша итдем дә, стансиядән өч-дүрт чакрым узаклыкда уфак тәпәчек[3] тарафына хәрәкәт итдем. Зира Петербург расадының рәисе профессор Витрам җәнабларының рийасәте тәхтендә[4] бер көн мөкаддәм бурайа килмеш һәйәт гыйльмия у уфак тәпәчек үзәренә карар итмеш иде.

Йул – аяк тутмаз кадәр чамурлы[5] иде. Зәхмәтлә мәшәкатьлә исә дә, Петербург расады карар итмеш мәркәзә ирешдем. Һәйәт гыйльмия алты-йиде мөнәҗҗимдән, ике-өч гүзәл рус мадамындан мөәлләф иде[6]. Күк йөзе хатеремдән чыкды. Мөнәҗҗимләрнең хәлләренә, әдәват расадияләренә күзем, дикъкатем махсур калды[7].

Бер урайа, бер бурайа кидүб, расад аләтләрене[8] тамаша итдем; һәйәт әгъзаларының хазирлекләренә, расад аләтләренең шәкелләренә мәфтүн улдым[9]. Ниһаяте йук әбгадның[10] иң хәфи[11] серләрене кәшеф ичүн[12] истигъмаль кыйлынур[13] расад аләтләренең шәкелләре бәнем күңелеми алды.

---

[1] галәбәлек – кеше күп булган урын.

[2] әдәват расадия – астрономик күзәтү кораллары.

[3] тәпәчек – калкулык.

[4] рийасәте тәхтендә – җитәкчелеге астында.

[5] чамур – пычрак.

[6] мөәлләф иде – гыйбарәт иде.

[7] махсур калды – тотылды; чикләнде.

[8] аләт – җиһаз, инструмент.

[9] мәфтүн улдым – хәйран калдым.

[10] әбгад – аралар; ераклыклар.

[11] хәфи – яшерен.

[12] кәшеф ичүн – ачыш ясау өчен.

[13] истигъмаль кыйлынур – кулланыла торган.

Уйлә дакыйкаларда дигәр[1] инсанларның күңелләренә бәлки шадлык килүр, ләкин бәнем күңелемдә у сәгатьдә гаять бөек инкисар[2] хасыйль улды. Зира дигәр милләтләрнең хәлләренә кыйас итмәдекчә[3], инсан үзенең хәлендән гафләт идәр, начар хәлләренә дә канәгать идәр, бәлки үзенең хәлейлә мәгърур улур, ифтихар идәр[4]. Фәкать үзенең хәлләрене дигәр милләтнең тәрәккыятейлә кыйас идәр исә, күзе ачык инсан үзенең хәлейлә ифтихар идәмәз, бәлки гаять бөек хәзинәләри әлендән заъигъ улмыш[5] да зәлил калмыш[6] инсанның тәъәссефе[7] кеби тәъәссеф идәр.

Бән дә у инкисар тәэсирейлә расад аләтләрендән күземи алдым, ун, унбиш хотувә[8] мәсафәдә үземнең әсбабыми тәртиб итдем. Әсбабым аз иде, эшем беркач саниядә тәмам улды. Вакыт – бер сәгать 30 дакыйка иде. Хазирләндем. Мөнәҗҗимләрнең хәбәренә күрә көсүф бер сәгать 33 дакыйкада ибтида кыйлынаҗак[9] иде.

Әтраф – тын! Кояш күземдә, сәгатем әлемдә, фикереми назарыми бер ноктада тупладым. Әсбаб фәләкиям[10], үземә күрә, гүзәл[11] иде. Түгәрәк табак шәкелендә кояш күрийурым[12]. Кояшның нурындан хәрарәтендән күзем ичүн бер зәхмәт, бер зарар йук кеби, гаять рахәт кояши тамаша идийурым.

Бер сәгать 33 дакыйка улды. Астда уң тарафда кояшда каралык күренде. Мөнәҗҗимләр мәгърифәтейлә тәгайен кый-

---

[1] дигәр – башка.

[2] инкисар – моңлану; күңел төшү.

[3] кыйас итмәдекчә – чагыштырмый торып; чагыштырмыйча.

[4] ифтихар идәр – горурлана.

[5] заъигъ улмыш – югалган.

[6] зәлил калмыш – артта, түбәндә калган.

[7] тәъәссеф – кайгы, хәсрәт; үкенү.

[8] хотувә – адым.

[9] ибтида кыйлынаҗак – башланачак.

[10] әсбаб фәләкиям – күк йөзен өйрәнү өчен кулланыла торган махсус кораллар.

[11] гүзәл – яхшы.

[12] күрийурым – күрәм.

лынмыш дакыйкадан бер сания бер салисә дә тәәххыр кыйлмайуб[1], камәр ирешде!

Йир йөзенең поездлары беркач дакыйкалар, беркач сәгатьләр тәәххыр идәрләр. Ләкин күк йөзенең поездларында һичбер вакыт бер саниялек дә, бер салисәлек дә тәэхир булынмайур!

Инсан буйлә сәгатьләрдә әһле һәйәтнең укадәр дакыйк хисабларына һәм тәгаҗҗеб идәр, һәм тәхсин идәр[2]. Әзәлдән[3] та шу сәгатә[4] кадәр бер саниялек хэлал[5] күрмәмеш гаять монтазыйм[6] хәрәкәтләри тәкъдир итмеш хикмәт илаһия газаматы, гыйззәте кыйбласында инсанның гакылы мөәббәд[7] сурәтдә сәҗдә идәр, йир йөзендә ислам мәсҗидләрендә миллион-миллион мөэминләр гыйззәт илаһия михрабларында, хикмәт илаһияйә сәна[8] укумак вазифасыйлә салят-ы көсүфи[9] әда идәр[10].

Көсүф башланды. Сәгатьнең дакыйкалык угы кеби, ай һаман хәрәкәт идүб кояш йөзене һаман сәтер идийур[11]. Түгәрәк кояш иске ай шәкеленә дә килде. Бөек урак сурәтенә керде, күчек бер даъирә илә капланub калмыш бер даъирә хәленә килде; гакыйбәт:

2 сәгать 47 дакыйкада кояшда халка шәкелле гаять гаҗиб тарыз[12] да заһир улды. Уртасы кара, әтрафы ут шәкелле күк йөзендә унбиш-йекерме сания кадәр мөддәт[13] калды. У дакыйкада камәрнең хәрәкәте һавада хәрәкәт идәр булут хәрәкәте кеби мәхсүс иде.

---

[1] тәәххыр кыйлмайуб – соңармыйча, соңга калмыйча.

[2] тәхсин идәр – сокланыр.

[3] әзәл – башланган мәле булмаган мәңгелек.

[4] та шу сәгатә – бу сәгатькәчә.

[5] хэлал – кимчелек, җитешсезлек.

[6] монтазыйм – төзек; төгәл тәртипкә салынган.

[7] мөәббәд – мәңге, мәңгелек.

[8] сәна – мактау, олылау.

[9] салят-ы көсүф – кояш тотылганда укыла торган намаз.

[10] әда идәр – башкара.

[11] сәтер идийур – каплый бара.

[12] тарыз – шәкел; форма.

[13] мөддәт – вакыт өзеге.

Халка шәкеле, мөддәтнең кысалыгы[1], камәрнең укадәр тиз хәрәкәте бәнем калебемә гаять куәтле тарызда тәэсир итделәр. У дакыйкада калебемә хатеремә «وَخَسَفَ الْقَمَرُ وَجُمِعَ الشَّمْسُ وَالْقَمَرُ»[2] айәт кәримәсе хотур итде.

Күк йөзендә заһир улмыш шу айәт табигыя – Коръән кәримдә инмеш у айәт кәримәйә тәфсир кеби тәлякъкый итдем. Калебемдә гаять бөек мәмнүният хасыйль улды.

Күк йөзендә заһир улмыш шу айәт табигыя, дидем, айәт коръәния тәфсиредер, йахуд айәт коръәния шу айәт табигыя тәрҗемәседер.

Шәмс[3] илә камәр бер ноктада мөҗтәмәгъ улды[4]. Ай кояши хасеф итде, ягъни бәзем күземездән гаъиб итде[5].

Шу тәфсирә күңелем канәгать итмеш кеби улды. Хисабы йук уфак һәм бөек тәфсирләремезнең тәфсирләренә калебем канәгать итмәз иде.

Галәл-хосус Тәфсир-е Рази кеби «ун куәтле әшкяль[6] йалңыз бер зәгыйфь тәүҗиһ[7] бәйан итмәк» ысулыйлә Коръән кәрим айәт кәримәләрене тәфсир идәр «тәфсир»ләрдән бән һичбер вакыт канәгать идәмәм.

Бәнем шу тәфсиреми Коръән кәримнең горефе дә тәэййид идәр[8]. Коръән кәримдә *хсф* маддәсе[9] алты дәфга зикер кыйлынуб, һәрбер дәфгадә һәм мәгълүм һәм мөтәгадди сыйгасыйлә[10] зикер кыйлынмышдыр. Һичбер айәт кәримәдә лязем

---

[1] кыса – кыска.

[2] «…ай караңгы ителеп кояш белән ай бергә кушылгач…» (Коръән, 75:8–9).

[3] шәмс – кояш.

[4] мөҗтәмәгъ улды – кушылды.

[5] гаъиб итде – юкка чыгарды.

[6] әшкяль – шәкел-нең күплек саны; шәкел – күренеш; форма.

[7] тәүҗиһ – аңлатма.

[8] тәэййид идәр – ныгыта, раслый.

[9] хсф маддәсе – хсф, ягъни ха-син-фа хәрефләреннән гыйбарәт булган сүз тамыры.

[10] һәм мәгълүм һәм мөтәгадди сыйгасыйлә – грамматик билгеле хәлдә һәм күчемле фигыль шәкелендә.

сыйгада[1] килмәмешдер. «Әл-Исра», «әс-Сабаъ», «әл-Мөлек» сүрәләрендә бер дәфга, «әл-Касас» сүрәсендә ике дәфга зикер кыйлынуб, һәр дәфгадә ике мәфгулә мөтәгадди[2] фигыль сыйгасында килмешдер.

Коръән кәримнең горефе әлбәттә хөҗҗәдер[3]. Һәм дә тәфсир хакында иң куәтле бер хөҗҗәдер. Буңа күрә «وَخَسَفَ الْقَمَرُ» айәт кәримәсендә фигыль би лә шөбһә[4] мөтәгадди улур[5].

Бәзем тәфсиремезне кыйраәт имамларының[6] иҗмагы да тәэййид идәр: кыйраәт имамларының һәммәсе, өммәтнең кяффәсе[7] «وَخَسَفَ الْقَمَرُ» айәт кәримәсендә фигыль(н)е – мәгълүм сыйга үзәрендә кыйраәт идәрләр.

Ислам галәменә мәгълүм сәбга, гашәрә, әрбәга-и гашәр, һәм гыйшрун кыйраәтләрнең[8] һәммәсе мәгълүм сыйгайә иҗмаг итмешләр. Кыйраәтләрнең һичберендә мәҗһүл бинасы[9] сабит дәгелдер[10]. Тәфсир-е Кәшшафның риваяте хатадыр.

Коръән кәримнең горефенә күрә «وَخَسَفَ» фигыле мөтәгадди улуб, һәм имамларның һәм өммәтнең иҗмагына күрә, мәгълүм улур исә, камәр хасиф[11] улуб, йагъни кояш(н)ы бәзем күземездән сәтер итмеш улур.

---

[1] сыйга – сүзнең грамматик шәкеле (формасы).

[2] ике мәфгулә мөтәгадди фигыль – эшне башкара торган ике субъектка караган күчемле фигыль.

[3] хөҗҗә – дәлил.

[4] би лә шөбһә – шөбһәсез.

[5] мөтәгадди улур – күчемле була. Бу очракта, (вә хасәфә) дип укылган «وَخَسَفَ» фигыле (вә хусифә) дип укылачак һәм «караңгыланды» түгел, «караңгы ителде» мәгънәсенә ия булачак.

[6] кыйраәт имамлары – Коръәннең сәхабәләр заманыннан сакланып килгән укылышларын белгән имамнар.

[7] кяффәсе – җитәрлек кадәр күпчелеге.

[8] сәбга, гашәрә, әрбәга-и гашәр һәм гыйшрун – ягъни: җиде имамның кыйраәте, ун имамның кыйраәте, ундүрт имамның кыйраәте һәм егерме имамның кыйраәте.

[9] мәҗһүл бинасы – билгесезлек шәкеле.

[10] сабит дәгелдер – расланмаган.

[11] хасиф (خاسف) – исем фигыль, ягъни: караңгылатучы.

Бәзем тәфсиремезә күрә, шу айәт кәримә көсүфнең сәбәбенә ишарә(н)е мөтәзаммин[1] улур, һәм дә көсүфнең вакытына да дәлаләт идәр. Йагъни көсүф – иҗтимаг дакыйкасында[2] камәрнең сәтерейлә[3] вакыйг улур.

Билүрем: «يَسْأَلُ أَيَّانَ يَوْمُ الْقِيَامَةِ فَإِذَا بَرِقَ الْبَصَرُ وَخَسَفَ الْقَمَرُ وَجُمِعَ الشَّمْسُ وَالْقَمَرُ يَقُولُ الْإِنسَانُ يَوْمَئِذٍ أَيْنَ الْمَفَرُّ»[4] айәт кәримәләре үлем сәгатьләрене йа кыямәт дәһшәтләрене бәйан сийакында[5] килмешдер. Дөрест, шуйләдер.

Ләкин Коръән кәримнең тәмамы, һәрбер сүрәсе, һәрбер җөмләсе, һәр айәт кәримәсе, айәт кәримә әҗзалары[6] – Коръәндер. Бер җөмлә үзенең сийакыйлә бер мәгънә(г)ә насыл дәлаләт идәр исә, у җөмләдән җөзеъ[7] улан айәт кәримәләр үзләренең мөстәкыйль мәгънәләренә дә әлбәттә уйлә дәлаләт идәр.

Дүрт биш айәт кәримә җөмләсе[8] бер мәгънәйи ифадә[9] йулында сәвыкъ кыйлынмыш исә[10], у айәт кәримәләрнең һичбере галәл-истикъляль[11] үз мәгънәләренә дәлаләтдән мәхрум улмаз.

---

[1] мөтәзаммин – үз эченә алучы.

[2] иҗтимаг дакыйкасында – кояш белән айның бер урынга килеп кушылулары минутында.

[3] камәрнең сәтерейлә – айның (җир шары белән кояш яктысыннан) каплануы белән, ягъни җир шарының күләгәсендә калуы белән.

[4] «Синнән: «соң ул Кыямәт көне» – дип сорый. Аң ачылып киткәч, ай караңгы ителеп кояш белән ай бергә кушылгач. Шул көнне кеше: «Кайларга гына йөгеререп (качарга) икән?» – диячәк». (Коръән, 75:6–10).

[5] сийак – контекст.

[6] әҗза (җөзъенең күплек шәкеле) – өлешләр, кисәкләр, парчалар.

[7] җөзеъ – өлеш, кисәк, парча.

[8] җөмлә – барысы бергә.

[9] ифадә – белдерү.

[10] сәвыкъ кыйлынмыш исә – юнәлдерелгән булса.

[11] галәл-истикъляль – мөстәкыйль сурәттә.

Буңа күрә «وَخَسَفَ الْقَمَرُ وَجُمِعَ الشَّمْسُ وَالْقَمَرُ»[1] айәт кәримәләре табигатьдә булынур хадисәләри тәфсир идә билүр.

Коръән кәримнең бәлягать гарәбиясендә вар игъҗазның бер җиһәте дә – бәйан-ы Коръәндә вар киңлекдер.

Шу фикерләр – халкайи мөшаһәдә санияләрендә күңелемезә хотур итде[2]. Күземези кояшдан алдык. Офык ихатасында күземези йөртдек. Күңелләрә дәһшәт вирә билүр бер караңлык күрдек, ләкин гариб бер караңлык иде. Күңелемдә вар тәэсири кайнатды. Инде күк йөзенә тәәссер күзейлә назар итмийә башладым.

Һәммә галәм кайгуйа батмыш! Күк йөзе «траур» кийүме, хәддад либасы[3] бөркәнмеш!

Дидем: гаҗәбән шу кайгу шигаре[4] нә ичүн имеш?

Хаҗи Зәйнелгабдин әфәнде Тагиев[5] кеби бер әһле һиммәтнең мәхкүмиятенә[6] күрәме йир йөзене караңлык басмыш?

---

[1] ай караңгы ителеп кояш белән ай бергә кушылгач

[2] хотур итде – искә төште.

[3] хәддад либасы – үлем-китем кайгысын чагылдыра торган кием.

[4] шигарь – билге, күрсәткеч; лозунг.

[5] Хаҗи Зәйнелгабдин Тагиев (1838–1924) – азәрбайҗанлы эшмәкәр, сәнәгатьче, сәүдәгәр, җәмәгать эшлеклесе, хәйрияче, дәүләт эшлеклесе. Шәкерт вә студентларга уку өчен стипендияләр түли, тулай тораклар төзи, матбугатчыларга газета-журналлар чыгаруда, язучыларга китапларын бастыруда хәлиткеч матди ярдәм күрсәтә. XX йөз башында казый Мирмөхәммәд Кәрим әфәнде тарафыннан азәрбайҗан теленә тәрҗемә ителгән Коръәнне бастыра. Бакуда үз исәбенә беренче театр бинасын төзетә, шәһәр халкын таулардан аккан саф су белән тәэмин итү өчен сууткәргеч суздыра. Санкт-Петербург җәмигъ мәчете төзелешенә дә үз өлешен кертә. Һиндыстанда (аның хәзерге вакытта Пакьстанга күчкән биләмәләрендә) башланган тагун (чума) эпидемиясе вакытында шунда 300000 ампула ашы (вакцина) җибәреп, куркыныч чирне җиңәргә ярдәм итә, шул эше аркасында аның исеме Пакьстанда ил тарихы дәреслекләрендә теркәлә.

[6] мәхкүмият – хөкемгә тартылу; судта хөкем ителү.

Хөсәен әфәнде Ямашев[1] кеби бер егетемезнең, Шакир әфәнде Рамиеф[2] бер рөкен-е милләтнең[3] шәһадәтенә вафатына күрәме күкләр, йолдызлар хәддад шигаре бөркәнмеш?

Йахуд шу өч фаҗига тәэсирейлә Русия мөселманларының калебләренә һөҗүм идән хәсрәтме һәммә галәм(г)ә гакес итмеш[4]?

Рахмани бер мәләк[5] тарафындан бәнем калебемә тәлкыйн кыйлынмыш шу тәүҗиһ хиссийат миллиямә дәһа зийадә муафыйк, мөляем улды. Бөек хәсрәтләремезә күкләрнең, йолдызларның, йир йөзенең иштиракьләрене[6] хис итдем дә, күңелемдә бераз тәслийә[7] хасыйль улды.

Шу тәслийә мөсагадәсейлә[8] күземи кояш тарафына тәүҗиһ итдем. Кояш йөзе у дакыйкада хәддад шигарене быракуб, тәмам нурыйлә галәми йактыртмыш иде. Шу кәйфияти бер фал кеби тәлякъкый итдем[9], дидем: иншаллаһ у өч мөхтәрәм зәватның карибләренә һәм дустларына шадлык сәгатьләре, сәгадәт көнләре шу кояш кеби парлак сурәтдә килүр! Ниһаяте йук киң фәзада[10] кояшның хәрәкәте кеби, иншаллаһ бәзем Хөсәен әфәндейлә хәйрат сахибы Шакир әфәнде дә Аллаһның ниһаяте йук рәхмәтләрендә та әбәд[11] карар идәрләр.

Шу өмидлә хәрәкәт итдем, бер сәгать имтидадында истансияйә килүб йитдем. Поезд хазир иде, биндем. Ике сәгать 30 дакыйка тарафында Петербура ирешдек.

---

[1] Хөсәен әфәнде Ямашев (Минһаҗетдин углы Хөсәен Ямашев; 1882–1912) – революцион хәрәкәт эшлеклесе, публицист.

[2] Шакир әфәнде Рәмиев (Мөхәммәтсадыйк углы Мөхәммәтшакир Рәмиев; 1857–1912) – алтын җитештерүче сәнәгатьче, сәүдәгәр, хәйрияче.

[3] рөкен-е милләт – милләт терәге.

[4] гакес итмеш – чагылган.

[5] мәләк – фәрештә.

[6] иштиракь – катнашу, уртаклашу.

[7] тәслийә – юаныч.

[8] мөсагадәсейлә – ярдәме белән.

[9] тәлякъкый итдем – кабул иттем.

[10] фәза – космос.

[11] та әбәд – мәңгегә.

Һәйәт әрбабы шу көсүф хадисәсендән гаять бөек файдалар истифадә итде. Бәзем Русия мөселманлары да, мөхтәрәм имам әфәнделәр дә шаядь уфак бер файда истифадә идәрләр: йагъни җөмадәл-үлә[1] башы хакында иттифак идәрләр.

Көсүф чәһаршәнбә көн улды. Пәнҗешәнбә көн горуб соңында[2] әлбәттә һиляль[3] күренүр. Җөмадә башында иттифак хәсебейлә[4], рамазан башында да иншаллаһ иттифак вакыйг улур. Шу файда бәзем ичүн гүзәл файдадыр.

Йукарыда йазылмыш айәт кәримәйи тәфсиремә күрә, Коръән кәримдә көсүф хадисәсе һәм сәбәбе һәм вакытыйлә зикер кыйлынмыш улур. Хөсүф хадисәсенә Коръән кәримдә ишарә йуклык – камәрнең фи затиһи[5] нурсызлыгына күрә улса кирәк.

---

[1] җөмадәл-үлә – мөселман календаренда ай исеме.

[2] горуб соңында – кояш баеганнан соң.

[3] һиляль – яңа туган ай.

[4] иттифак хәсебейлә – берләшү исәбенә; берләшү аркасында.

[5] фи затиһи – үз башына; табигатенә күрә.

## «Я, было, огорчился, но теперь понял»[1]

В газете «Танин»[2] от 25 марта 1329[3] года я прочитал сообщение под названием «Из высших духовных кругов». В сообщении речь идет о том, что Машихат исламия[4] направила в адрес Министерства внутренних дел указание в отношении четырех моих книг[5], в которых якобы присутствуют ереси и они мол написаны для того, чтобы ввести мусульман в заблуждение. По этой причине исполнительным органам Министерства внутренних дел рекомендуется конфискация этих книг повсеместно, где они только будут обнаружены. Я несколько раз внимательно прочитал это сообщение, однако не почувствовал в душе ни капли горечи.

---

[1] Источник: Муса Бигиев. Тәәссеф итмештем, артык, аңладым // Вакыт. 1913. 8 июнь. (Перевод с татаро-османского наш)

[2] «Танин» – турецкая газета, основанная в 1908 году османским поэтом – создателем современной турецкой поэзии – Тевфиком Фикретом (наст. имя: Мехмет Тевфик, 1867–1915), в которой он поддерживал правящую партию İttihat ve Terakkî (Единение и прогресс). 26 декабря 1908 г. Т.Ф. по идеологическим соображениям покинул газету. В целом, газета выходила с 1 августа 1908 г. по 31 октября 1918 г. Всего вышло 3550 номеров газеты.

[3] 1329-й год хиджры соответствует 1911-му году по григорианскому летосчислению, март – месяцу рабиъуль-авваль.

[4] Машихат исламия – государственный орган османского государства, Управление делами шейхульислама – высшего должностного лица по вопросам ислама в Османской империи.

[5] Речь идет о таких книгах Бигиева, как «Рәхмәт илайия борһанлары» (Доказательства Божьей илости); «Инсанларның гакыдә илаһияләренә бер назар» (Взгляд наверование людей в божество); «Озын көнләрдә рузә» (Пост в долгие дни) и «Кавагыйд фикъһия» (Правила фикха).

Критические отклики, касающиеся моих книг и опубликованные на страницах таких изданий как «Шура»[1], «Вакыт»[2], «Тарджуман»[3], «Кояш»[4], «Идел»[5] и «Йолдыз»[6] оказали на меня некоторое воздействие. Но это распоряжение шейхульислама[7] совершенно не оказало какого-то влияния. Я не придал никакого значения фетве и указу шейхульислама. Более того, запрет, наложенный на мои книги после того, как они

---

[1] «Шура» («Совет») – первый татарский литературный и научно-популярный журнал, издававшийся в Оренбурге в 1908–1917 годах. Всего вышло 240 номеров.

[2] «Вакыт» («Время») – татарская национальная либерально-демократическая газета, издававшаяся в г. Оренбурге в 1906–1918 гг.

[3] «Тарджуман» («Переводчик») – общероссийская тюрко-татарская газета, которая выходила с 1883 по 1918 год в Бахчисарае и фактически была печатным органом тюркоязычного населения Российской империи. Основателем и издателем был крымско-татарский просветитель Исмаил Гаспринский.

[4] «Идел» («Волга») – общественно-политическая газета, издавалась с 1907 года. Выходила 2–3 раза в неделю и входила в пятерку наиболее массовых и влиятельных татарских газет России. В 1913 году по решению департамента полиции газета была закрыта «без права возобновления».

[5] «Кояш» («Солнце») – татарская общественно-политическая, литературная газета либерально-демократического направления, не следующая программе ни одной партии. Выходила в свет в Казани с декабря 1912 г. по июнь 1918 г. Всего было издано 1245 номеров.

[6] «Йолдыз» («Звезда») – татарская общественно-политическая газета, издававшаяся в Казани с 1906 г. Распространялась по всей России и Средней Азии. Максимальный тираж доходил до 8 тысяч экз.

[7] шейхульислам (старейшина ислама) – титул высшего должностного лица по вопросам ислама в Османском государстве. Данного титула удостаивались ведущие богословы, которые досконально знали исламскую правовую традицию и могли применять религиозные нормы к новым, ранее не трактовавшимся случаям. В период написания Бигиевым своей статьи шейхульисламом Османской империи являлся Мехмет Эсад Эфенди (1847–1918), занимавший этот пост с января по 11-е июня 1913 г.

на протяжении трех-пяти лет сотнями распространялись на базарах Стамбула, отнюдь не вверг меня в печаль.

14 апреля я получил письмо из Стамбула. В этом письме, отправленном руководством одного известного и уважаемого издания, были и следующие строки: «*Несмотря на то, что со стороны шейхульислама поступило указание о конфискации Ваших книг, теперь они расходятся в еще больших количествах. У наших читателей, начиная от учащихся медресе, день ото дня растет желание познакомиться с вашими трудами*».

Через два дня я получил из Стамбула еще одно письмо. Оно было от самого известного стамбульского книготорговца. Он писал: «*Несмотря на то, что шейхульислам наложил запрет на четыре Ваших сочинения, мы не отказались продавать их. Пожалуйста, доведите до сведения издателя Алима эфенди Максудова*[1]*, чтобы он издал новый тираж, добавил бы к нему то, что осталось от прежних тиражей и отправил бы нам, добавив туда же ваше новое сочинение «Халык назарына»*[2]*. Просим его не проигнорировать нашу просьбу и поспешить*».

После того, как я прочитал эти два письма, у меня испортилось настроение. Действительно, есть от чего огорчиться, ведь, если подумать, в центре исламского Халифата из таких

---

[1] Мухаммет-Алим Рахимович Максутов – видный представитель петербургской татарской диаспоры, купец, общественный деятель, издатель. В его типографии был издан ряд книг Мусы Бигиева. В январе 1906 года Максутов предоставил свой дом для проведения заседания участников II Всероссийского съезда мусульман, поскольку власти не дали официального разрешения на созыв этого мероприятия.

[2] «Халык назарына» (Вниманию публики; оригинальное название книги – «Халык назарына берничә мәсьәлә». Казань: Умид, 1912. 93 с.). Данный труд Бигиева представляет собой сборник написанных в публицистическом жанре статей, в которых он затронул и исследовал наиболее актуальные социальные, культурологические, религиозные и этические проблемы, стоявшие перед татарской и российской мусульманской общественностью.

высоких кругов как Машихат исламия издается распоряжение за подписью представителя исламского шариата – шейхульислама хазретлери, однако на базарах Стамбула, в кругах книготорговцев этот высокий указ не стоит и ломаного гроша! Меня очень огорчило, что учащиеся мусульманских медресе считают должным не подчиняться указам шейхульислама и что они игнорируют шариатские постановления. Это показывает, что после возникшей в Османской империи политической анархии возникла еще и анархия шариатская.

Я спросил себя: «Почему указы шейхульислама, которые раньше почитались во всем мусульманском мире, ныне остаются без внимания мусульман, кроме одного-двух книготорговцев?» Нет вреда в том, что запрещена продажа моих книг на базарах Стамбула, ведь если сегодня они запрещены, то завтра, возможно, будет оглашен прямо противоположный указ. Но главное, что вызывает сожаление, это то, что распоряжениям шейхульислама хазретлери совершенно не придается значения на базарах Стамбула.

В ответном письме книготорговцу, написавшему мне письмо из Стамбула, я изложил следующую просьбу: «Если шейхульислам хазретлери запретил продажу моих книг, то не продавайте их! Особенно внимательным нужно быть в исполнении шариатских постановлений». Наконец, 17го апреля я получил из Стамбула еще одно, теперь уже третье письмо. А еще раньше, 10го апреля, мне было отправлено письмо от издательства журнала «Тюрк Йурду»[1], в котором тоже говорилось: «Поскольку Министерство внутренних дел не приняло к рассмотрению распоряжения шейхульислама о конфискации Ваших книг, он отозвал своей распоряжение».

Меня это сообщение огорчило подобно тому, как огорчило и первое сообщение. Мою душу коробил тот факт, что распоряжения, которые на протяжении веков являлись главными

---

[1] «Тюрк Йурду» – ежемесячный турецкий журнал, который впервые вышел 30 ноября 1911 года. Издание было основано представителями татарской и азербайджанской диаспоры в Турции Йусуфом Акчурой, Ахметом Агаоглу, Али Гусейнзаде.

предписывающими актами по самым важным вопросам, ныне оказались бессильными в решении самых простых проблем.

Были времена, когда турецкие сабли, находившиеся в надежных руках, казались самыми сильными в мире политики, но время шло, и определенные исторические причины и обстоятельства привели к тому, что политическая сила Турции ослабла. То же самое произошло и с указами шейхульислама, которые раньше считались священными: в силу исторических причин они стали бессильными и игнорируемыми.

Если сегодня книготорговцы и учащиеся не обращают внимания на распоряжения шейхульислама, то вину не следует искать в книготорговцах или шакирдах. Вину за сложившееся положение нужно искать в истории Машихат исламия, в самих шейхульисламах.

Когда мы обозреваем историю Османского государства внимательным и беспристрастным взором, то видим, что во всех малых и больших изменах и пороках, которые привели к краху государства и нации, первую роль играли шейхульисламы, армия шариатских судей и служители культа. Султан Беязид[1], из-за тогдашних факихов и муфтиев, погубил своего сына и двух братьев.

Практика осуществления варварских убийств от нескольких до двадцати невинных шейхзаде (принцев) в периоды перехода престола, внедренная после правления султана Беязида[2], укрепилась благодаря фетвам шейхульисламов и ка-

[1] Беязид (Беязид I Молниеносный; Беязид Йылдырым; 1354/55/57–1403) – 4-й правитель и 2-й султан Османской империи, правивший в 1389–1402 гг., сын султана Мурада I. Баязид известен своими военными успехами и получил прозвище Молниеносный за умение быстро перемещать войска.

[2] Речь идет о т.н. «Законе Фатиха» из Канун-наме (Свода законов) султана Мехмеда II Фатиха (1432–1481), который позволял наследнику османского трона, которому удалось стать султаном, физически устранить остальных претендентов на престол. Известно, что султан Мехмед III, правивший в 1595–1603 гг. при вступлении на престол отдал приказ о казни своих малолетних братьев, которых у него было девятнадцать.

диев, которые придавали своим указаниям самые пристойные формы и оправдывали их жизненной необходимостью.

Специализацией мулл и кадиев стало протежирование назначения на высокие посты предателей, которые смещали со своих постов надежных и умелых Великих визирей, и министров.

Шейхульисламы и кадии более всего преуспели в превратном толковании установлений шариата и продаже фетв для того, чтобы уважить султанов и пашей, создать им «богословски обоснованные» условия для взяточничества.

Привлечение янычаров[1], разграбивших казну, к дворцовым переворотам и к преступлениям изменников, стало самым лакомым кусочком для ненасытных глоток шейхульисламов и кадиев.

Нам известны имена невежественных кадиев и надменных муфтиев, деяния которых были раскрыты перед ничтожными притязаниями одного типа – беспутного разгильдяя Муллы Кябиза[2].

[1] янычары (от тюркск. йени чери, т.е. новое войско) – регулярная пехота, одна из трех ударных сил Османской армии в период времени с 1365 по 1826 гг. Янычары официально считались рабами султана и постоянно жили в монастырях-казармах. До 1566 г. им было запрещено жениться и обзаводиться собственным хозяйством. Корпус янычар со временем трансформировался в фактически самостоятельную мощную консервативную политическую силу, использовавшуюся как инструмент свержения султанов. Так, бунты янычар привели к свержению и гибели султанов, например, в 1622, 1623 и 1807 гг.

[2] Мулла Кябиз – живя во времена Сулеймана Справедливого, выдвинул учение о том, что Иисус стоит выше Пророка Мухаммада и приступил к распространению своих взглядов. По приказу тогдашнего Великого визиря Ибрагима-паши, он был схвачен и доставлен во дворец. Его судили кадий Румийской области Фенари-задэ Мухиддин и кадий Анатолийской области Кадири Эфенди. Эти судьи не смогли опровергнуть доказательства Моллы Кабиза и вынуждены были освободить его. Когда султан Сулейман спросил о причинах освобождения Кабиза у своего Великого визиря Ибрагима-паши, он ответил, что дело в некомпетентности кадиев.

Всем известно, как повели себя шейхульисламы, кадии и муфтии, на протяжении всей истории игравшие главные роли во всех изменах, пороках и зле, когда султан Селим III[1] решился провести реформирование Османского государства. Кто, как ни они, стал причиной неописуемо ужасной мученической смерти главы государства после того, как ими было оказано всяческое противодействие начатым им самым необходимым и важным реформам?

Почему Османское государство протянуло свою немощную руку французским законам? Почему были отстранены Благородный Коран и исламский шариат? Почему чудесный исламский шариат превратился в набор текстов и книг фетв, по которым нельзя было решить никакие вопросы? Машихат

---

Кабиза вновь доставили во дворец. На этот раз суд возглавлял шейхульислам Ибн Камал и он вынес решение о смертной казни обвиняемого. (См.: M. Germez. Musa Carullah Bigief. Для более полной информации о М. Кабизе см.: H. Gazi Yurdaydin. Islam tarihi dersleri. A.U/ Ilahiyat Fak. Yay N: 154. Ankara, 1982. S.111–113).

[1] Селим III (1761–1808) – 28-й султан Османской империи, правивший в 1789–1807 гг. Намеревался реорганизовать и модернизировать Османское государство по европейскому образцу, в том числе и армию. Уже в 1789 г. начал реализовывать амбициозный план по внедрению бесплатного и обязательного начального образования. Для этого он разработал первую в истории государства систему государственного образования, предусматривавшую законченную систему начальных и средних школ, а также университетов, для управления которыми создал Министерство образования. По объективным причинам его возможности были ограничены, например, после вторжения Наполеона в Египет в 1798 г. Селим III был вынужден вести войну с Францией. С 1802 года приступил к претворению в жизнь преобразований в области административного аппарата, упразднил военное управление ленных владений, чем задел интересы янычарского корпуса. Кроме этого, султан поручил французскому генералу Себастиани создание т.н. Низам-и Джедид (Нового порядка), т.е. армии, организованной по европейским принципам. В итоге был свергнут взбунтовавшимися янычарами, вдохновленными фетвой шейхульислама против реформ. Был убит во дворце в ходе возникшей смуты.

исламия в лице всех его сотрудников явился средством или лидером всех пороков. Именем шариата он объявлял войну всем реформаторским идеям и движениям и оказывался победителем. В конце эпохи невежества и бездеятельности, когда этот орган, который не делал ничего, кроме мучительного заучивания бесполезных книг по тем или иным фетвам, произошел отказ от исламского шариата, который якобы стал непригодным.

Вот таковы свидетельства истории о Машихат исламия…

Я не имею каких-либо знакомств и связей с представителями Машихат исламия. Но, когда происходило опорочивание величия ислама, тюркского достоинства и чести наших женщин, Машихат исламия молчал, он сладко спал. Он проявил полное бессилие, не воспользовавшись великой силой, которой владел.

Читая в прессе фетвы Машихат исламия касательно войны на Балканах, мы стали свидетелями того, насколько члены этой организации далеки от шариата! Фетвы, даваемые ими по поводу расходов на нужды военного флота и боевых действий, доказывают небрежность и невнимательность Машихат исламия к шариату.

Да, фетва о молитве, которую следовало читать 4444 раз[1], была, по моему мнению, «прекрасной» фетвой. Это было шуткой, произнесенной в мире ислама языком Ходжи Насреддина. Мы не поняли той шутки. Мы смеялись, выпуская статьи против шуток Ходжи Насреддина. Грех был на нас. Но на Машихате исламия лежит грех за такой недостаток как

---

[1] В османской прессе начала XX в. под эгидой Машихат исламия продвигалась идея о необходимости совершения 4444 богопоминаний-зикров, для того, чтобы молитвы мусульман о достижении победы в Балканских войнах были услышаны и приняты Аллахом. При этом, не существует аятов Корана или хадисов пророка, свидетельствующих о том, что молитва или молитвы обязательно должны быть прочитаны 4444 раза. По этой причине, фетва шейхульислама о 4444-кратном зикре являлась ничем иным, как узакониванием предрассудков, что и подчеркивает Бигиев.

неспособность сказать серьезные вещи и превращение разговора в шутку.

Внутренний раздор в партиях, и даже поражения в Балканской кампании[1] есть ничто по сравнению с таким состоянием членов Машихат исламия и турецких мулл.

Интересно, какой грех был в моей книге «Кавагыйд фикхия»[2], которую я подготовил, собрав самые приемлемые правила из самых надежных источников?

Согласно формулировкам, имеющимся в постановлении шейхульислама, оказывается, что «в «Кавагыйд фикхия» много отсебятины». Это верно – в «Кавагыйд фикхия» есть два момента, разработанные мною с опорой на принцип иджти-

---

[1] Балканские войны – две военных кампании, имевшие место в 1912–1913 годах, в результате которых страны Балканского полуострова потеснили осман с европейской территории. Первая война была начата т.н. Балканским союзом в лице Сербии, Черногории, Греции и Болгарии, которые планировал полностью лишить Османскую империю владений в Европе. Эта цель была почти достигнута. Вторая кампания была вызвана разногласиями между победителями, приведя к развязыванию войны между Болгарией, с одной стороны, и Сербией, Грецией, Румынией, Черногорией и Османской империей – с другой. Болгария была побеждена и лишилась большей части своих приобретений в первой войне, Османская империя вернула Адрианополь с окрестностями.

[2] «Кавагыйд фикъһия» (Правила фикха; полное название: «Шәригать исламия әлифбасы мөсабәсендә игътибар кыйлына билүр кавагыйд фикъһия», т.е. Пригодные для использования в качестве азбуки исламского шариата правила фикха) – правовой сборник, составленный Бигиевым в 1910 г. в русле исполнения просьбы Р. Фахретдина о создании шариатского журнала для российских мусульман. В этом сборнике, наряду с правилами, заимствованными из османского шариатского журнала «Маджалла ахкям-и адлия», было изложено более 200 правил фикха со ссылками на соответствующие аяты Корана и предписания суннитских мазхабов. На страницах сборника Бигиев продолжал развивать социально значимые положения лучших образцов средневековой исламской юридической теории и практики, сформулировав на их основе собственную методологию права.

хада, которые можно назвать отсебятиной. Я привел их оба. В нескольких местах я легко отнес на свой счет совершенно открыто повторявшиеся в шариатской науке вещи. Я лишь показал эти вещи, не скрывая ни одного мнения. И вообще, я не написал ничего, что могло бы вызвать кривотолки. Первый момент – это вопрос о наказании за вероотступничество, второй – проблема рабства.

Согласен, мысль, которую я выразил по первому вопросу, полностью идет в разрез с тем, что на протяжении шести веков совершал Машихат исламия. Ибо примеры убийств тех, кто совершал самые благие дела для государства, жил верной, преданной ему жизнью, в истории Османского государства исчисляются сотнями и тысячами. Но в истории Машихат исламия нет ни одного случая, когда бы был казнен кто-либо из тех вероотступников, который оскорбил шариат, предав государство и отчизну.

Да, я опровергаю решение о наказании, налагаемом на вероотступника. Но, при этом, я не являюсь сторонником милосердного отношения к тем, кто оскорбляет наши священную религию и предает нашу священную отчизну, подобно тому, как милосердно с ними обращаются шейхульисламы.

Во втором вопросе, т.е. проблеме рабства, также имеется совершенно очевидная разница между фетвой шейхульисламов и моим мнением. Поэтому шейхульислам, конечно же, вправе назвать мой взгляд «ошибочным и вздором».

Несколько [десятков] лет тому назад, когда на земли Османского государства переселялись черкесы[1], из-за «прекрасных» постановлений государственных деятелей (!) они массами стали гибнуть от голода и нищеты в вилаетах Самсун

[1] Имеется в виду т.н. Черкесское переселение (Черкесское мухаджирство), представляющее собой массовый исход черкесского народа, абазов, абхазов и убыхов, спасающихся от истребления, с Кавказа в Османскую империю во время ведения, и после окончания Кавказской войны 1817–1864 годов, когда, в ходе колониального завоевания Кавказа, Российская империя вступила в непосредственный конфликт с Османской империей.

и Трабзон. Люди, посланные Великим визирем Али Пашой[1], следуя изданной тогда фетве шейхульислама, продавали оставшихся без родителей девочек-сирот за пять-десять курушей[2] на базарах Стамбула, низвергая их в вертепы порока, превращая в наложниц.

Традиция ежегодных поставок в благие вечера и ночи[3] во дворцы знати в качестве даров черкесских или грузинских наложниц; обеспечение правителей и их досточтимых гостей красавицами-рабынями. Если это безобразие и совершалось без специальных фетв шейхульисламства, то оно совершалось, вне всякого сомнения, с их помощью и с их согласия. При попустительстве Машихат исламия такое положение дел превратилось в совершенно обычную практику. Захваченные в набегах полонянки доставлялись в Стамбул, и ими пользовались в качестве «мульк-и йамин»[4] как шейхульисламы, так и кадии.

---

[1] Али Паша (Мехмет Эмин Али Паша; 1815–1871) – государственный деятель Османской империи, великий визирь, занимавший этот пост несколько раз. Один из лидеров программы реформ в империи, известных как Танзимат.

[2] куруш (от лат. grossus) – поначалу в Османской империи так назывались серебряные европейские монеты, затем с 1687 г. стал национальной денежной единицей, которую чеканил монетный двор султана Сулеймана II. В XIX в., в т.ч. и в период описываемых событий вес куруша постепенно снижался от 4,65 грамм серебра в 1810 г. до 1,2 грамм в 1910 г. В русском языке заимствовано в форме грош, в арабском – кырш.

[3] Подразумеваются ночи священного месяца рамазан.

[4] мульк-и йамин – раб, рабыня или наложница (даджрия), являющаяся, с позиции шариата, чьей-либо собственностью.

В одной из османско-иранских войн[1] была захвачена в плен жена Надир-шаха[2]. Согласно фетве главного турецкого шейхульислама, она была отдана в качестве постельной принадлежности одному из величайших турецких правителей.

Из миллиона подобных случаев мы коснулись лишь нескольких примеров. И если такие решения разрешены и допустимы согласно фетвам шейхульисламов, то, согласно моей «отсебятине», они совершенно недопустимы и являются харамом! Может быть именно поэтому мои слова, которые противоречат поступкам и фетвам всех шейхульисламов, кадиев и муфтиев, оправдывавшихся понятием «мульк-и йамин», и были объявлены «ошибкой и вздором»?!

Проблему рабства я осветил на 184–193 страницах «Кавагыйд фикхия». Если вы будете называть это моей отсебятиной, то я буду только рад.

Ничто в этой книге, кроме названных выше двух вещей, не является моим личным мнением и не основано на принципе иджтихада. Все они являются общими приемлемыми правилами, выведенными из самых надежных источников.

Я помню страницы и строки приводимых мною выдержек и ссылок. Если и появится некто, который заявит, что

---

[1] Бигиев имеет в виду Турецко-персидскую войну 1743–1746 годов, которая была по инициативе Надир-шаха (см. ниже), после того, как он, будучи шахом Ирана, дважды (в 1736 и 1740 гг.) предложил османскому халифу, чтобы шиизм двунадесятников, принятый около 1500 года как религия государства Сефевидов, теперь считался бы пятым направлением суннитского ислама. Халиф оба раза отклонил это предложение.

[2] Надир-шах (Надир-шах Афшар; ум. 1747) – шах Персии в 1736–1747 годах, основатель тюркской династии Афшаридов, полководец. Организовал завоевательные войны, приведшие к созданию обширной империи, в которую, кроме Ирана и Азербайджана были включены (в качестве провинций или вассальных территорий) Армения, Грузия, часть Дагестана, Афганистан, Белуджистан, Хивинское и Бухарское ханства. В 1737–1738 гг. Надир-шах начал поход в Северную Индию, а в 1739 году захватил Дели – столицу тюркской династии Великих Моголов.

«на такой-то странице то-то является безосновательным», то я смогу назвать страницы источников, на которые опирался в ходе работы над книгой.

Если книги ханафитского мазхаба не являются «ересью и вздором», то и в моих «Правилах» нет и не может быть ошибок и пустословия. Если же те книги полны всякой чепухи, то и моя книга окажется чушью.

Круги Машихат исламия славны и, несмотря на все сказанное выше, институт исламских шейхов для меня свят. Слава государства напрямую связана с действенностью и силой института исламских шейхов. Надо думать, что слова таких слабых рабов как мы, наверное, не соответствуют ни достоинству Машихат исламия, ни объективным требованиям эпохи.

Сегодня нет необходимости приноравливать шариат к запросам и требованиям цивилизации. Напротив, следует привести институт шейхульисламов в соответствие с шариатом.

Если вы и убедили несчастных мусульман «проглотить» вашу ложь о продаже книг в банковских операциях, прочитайте, все же, аяты из суры «Бакара» о Великом правительстве. И категорически запретите получение кредитов из европейских банков. До Крымской войны[1] у нашего государства не было ни копейки долга. Не берите руками банкиров золото из европейских кладовых. Берите своими силами и из своей казны. До Крымской войны у нас не было долгов, пусть также будет и теперь.

Хоть один раз за всю вашу историю поступите так, как велит Благородный Коран. Вас может спасти только Коран.

---

[1] Крымская война – война 1853–1856 годов война между Российской империей, с одной стороны, и коалицией в составе Британской, Французской, Османской империй и Сардинского королевства – с другой.

# «Мой взгляд на исламский Шариат»[1]

Я решил представить свой взгляд на исламский шариат[2]. Для того, чтобы свободно и доходчиво вести речь об установлениях шариата применительно к жизни индивида и, в целом, общества, в первую очередь совершенно необходимо определить наш взгляд на шариат. Пока мы не определимся с нашим подходом к священному шариату, невозможно будет свободно провозглашать правильные ответы и в приемлемой форме претворять их в жизнь.

До тех пор, пока мы не определимся с нашим отношением к шариату, нам всегда будет трудно, всегда будет тяжело. Те ситуации, когда возникнет необходимость достижения всестороннего соответствия шариата нашим общественным проблемам, и, наоборот – наших общественных проблем священному шариату, будут трудноразрешимыми. Будут продолжаться жалобы на установления шариата. В конце концов шариат, подобно совершенно ненужной вещи, окончательно потеряет свое применение в практике.

Если мы взглянем на имеющиеся исламские течения мысли, то увидим присущую им свободу. Если мы обратим наш внимательный взор на такие страны как Турция и Египет, которые ступили на путь вестернизации, то вместо чудесного шариата мы там увидим французские законы и английские правовые системы. В таких отраслях, как политические права, управление, и иные аспекты общественного устройства, совершенно не осталось обращения к шариату. Исламский шариат везде и всесторонне вышел из употребления. В то время, когда законы и правовые системы всех народов развиваются, привлекая внимание цивилизованного мира, в му-

[1] Источник: Муса Җаруллаһ. Шәригать исламияйә бәнем назарым // Ил. 1913. № 1–3. (Перевод с татаро-османского наш).

[2] шариат – канонический исламский религиозный закон.

сульманском мире закон Благородного Корана и мудрого Пророка (ﷺ), по какой-то причине, отстранен от использования на практике.

Нет сомнения в том, что сегодня нельзя не понимать и не видеть эту очевидную реальность. Не вызывает сомнений также и то, что отвергать эту реальность, после того как она понята и увидена, просто греховно.

Человек, изучивший древние и новые законы, известные в цивилизованном мире, и хорошо знающий исламский шариат, описывая эту правду будет удивлен и поражен.

Я также осознавал для себя эту горькую правду. Сравнивая необыкновенную активность западного мира и нашу крайнюю пассивность, я всегда и по всем вопросам стыдился за нас. С одной стороны, я глазами влюбленного взирал на величие, широту и великолепие нашего священного шариата, а с другой стороны, глазами, полными надежд, искал способы преодоления и спасения из этого печального положения.

Меры для исправления нашего состояния были известны, пути спасения были открыты и правильны. Я вышел на один из самых верных путей.

Прежде всего, нам необходимо провести межевание между исламскими мазхабами[1] и исламским шариатом. Нужно научиться проводить границу между тафсирами[2] комментаторов Корана и целями Законодателя. Мазхаб – это одно, а исламский шариат – другое. Тафсир – одно, священный аят – другое.

Отрицание какого-либо мазхаба или критика какой-либо известной проблемы, имеющейся в том или ином мазхабе, ни в коей мере не является отрицанием собственно шариата или критикой, направленной в его адрес. Критика тафсиров

---

[1] мазхаб – в широком смысле термин, обозначающий течение в мусульманской теологии, фикхе и суфизме. В узком смысле – обозначание правовых школ в суннитском исламе, названных по именам их основателей: ханафитский (имам Абу Ханифа), ханбалитский (имам ибн Ханбал), маликитский (имам Малик), шафиитский (имам аш-Шафии).

[2] тафсир – толкование Корана.

Корана, или признание какого-либо из них совершенно ошибочным, не означает, что критике повергаются сами священные аяты, или что в их отношении выдвигаются обвинения в ошибочности.

Итак, совершенно необходимо разделение мазхаба и собственно шариата, тафсиров Корана и собственно священных аятов. Если это простое условие будет принято за основу, то в дальнейшем будет легче решать трудные вопросы, которые называются «религиозным реформаторством» и «социальным переустройством».

В человеческом обществе приняты и действуют несколько правовых систем. По моему мнению, все они достойны уважения и почитания. Если мы сравним известные на Западе правовые системы Рима, иудаизма, Египта с имеющимися в мусульманском мире правовыми мазхабами, то выяснится, что наши мазхабы в большей степени соответствуют требованиям социальной реализации индивида. Если мы измерим их на весах предпочтения, то выяснится, конечно, что наши мазхабы стоят выше римской правовой традиции.

Мне, конечно же, неизвестна подробная история правовых школ мусульманства. Мне неизвестно, пользовались ли наши великие имамы[1] опытом римского права и иудейскими книгами или нет. Но в первые века ислама, когда на земле арабов не было и следа римского права, основы мусульманских мазхабов были заложены в наилучшем виде.

Такие известные мазхабы как ханафитский, шафиитский, ханбалитский являются продолжением тех великих мазхабов, которые сложились в начале эры ислама. Имамы, разработавшие те великие мазхабы, конечно же, ничего не ведали ни о римском праве, ни об иудейских книгах. Эти имамы, глаза коих были ослеплены великолепием ислама, конечно, не могли, при этом, разглядеть римские законы и иудейские талмуды. Эти великие имамы, удовлетворенные Благородным

[1] имам – предстоятель и руководитель коллективной молитвой мусульман; глава мусульманской общины; в широком смысле – знаток мусульманской религии, религиозный ученый.

Кораном и установлениями Великого законодателя[1], конечно, не считали нужным использование римских законов и иудейских талмудов.

Это значит, что, разрабатывая исламское право в рамках того или иного мазхаба, наши великие имамы, судя по всему, не обращались к талмудам и римским законам. Наши правовые мазхабы возникли, как мне кажется, не путем заимствования законов, применявшихся ранее, но только благодаря самостоятельному иджтихаду наших великих имамов.

Если мы примем во внимание, что иные правовые системы были лишены этого важного качества, то нельзя не восхититься совершенством и способностями наших великих имамов.

Поэтому я в высшей мере уважаю исламские мазхабы. Наши мазхабы, созданные без какого-либо подражания древним законам и ничего не заимствовавшие из древних книг, являются, по моему мнению, одним из чудес ислама. Исламское право и мазхабы – это уникальная вещь, редко встречающаяся в истории права и законотворчества.

Мазхабы были созданы великими имамами. Но они не преследовали цель насильно навязать свои мазхабы мусульманам и создавали их не для того, чтобы ограничить шариат установлениями мазхаба и собственными взглядами. Скорее, они делали это для того, чтобы продемонстрировать каждому члену уммы[2] способы и пути применения Пророческой сунны[3] в любой ситуации, возникающей в жизни общества согласно условиям той или иной эпохи и сообразно с принципом целесообразности.

«*Если постигнет истину – воздастся двукратно. Если ошибется – воздастся единожды*». Этот хадис нашего Священного Посланника, Пророка и Законодателя (ﷺ) является официально провозглашенным универсальным правилом для каждого слова, изрекаемого каждым имамом.

---

[1] Великий законодатель – пророк Мухаммад.

[2] умма – мусульманское сообщество, нация правоверных.

[3] сунна – совокупность преданий-хадисов об изречениях, деяниях (в т.ч. поведении) пророка Мухаммада.

Этот хадис, который был провозглашен для того, чтобы разбудить в имамах различных мазхабов стремление к иджтихаду, определил эвристическую ценность мазхабов. Каким бы замечательным ни было общее устройство какого-либо мазхаба, в нем всегда можно обнаружить те или иные ошибки и изъяны.

Если ошибка означает потерю доказательств и уход с верного пути в вопросах, которые должны решаться силой разума, то ошибка в политических процессах и общественных проблемах означает потерю выгоды, утрату пользы и отход от путей и способов решения жизненно важных вопросов.

Выгода, интерес и целесообразность весьма разнообразны и зависят от времени, от локации, от состояния и разнообразия самих людей. Поэтому школы фикха, основанные с целью налаживания жизни людей во всех ее проявлениях, не могут быть ни вечными, ни всеохватными. В силу этого, решение, которое было верным в определенное время, для определенных ситуаций и для определенных людей, не всегда оказывается подходящим для событий и людей, живущих в последующие времена.

Таков мой взгляд на мазхабы…

Наши мазхабы фикха являются драгоценным наследием, которым мы должны пользоваться. Но они ни в коей мере не являются грузом, который должен наносить нам вред и ввергать нас в бедствия. Если решение одного из мазхабов по какому-либо вопросу ставит нас в трудное положение, то мы, несомненно, должны отвергнуть это решение. Фанатический таклид[1] установлениям, которые могут нанести урон тем или иным аспектам нашего общественного состояния, конечно же, является грехом.

Несмотря на то, что такие уважаемые мазхабы как маликитский, ханафитский, шафиитский и ханбалистский совершенны по своей структуре, известно, что в них немало

---

[1] таклид – безоговорочное следование в рамках того или иного мазхаба решениям древних авторитетных правоведов (факихов) по правовым вопросам жизни мусульман.

признанных ошибочными вопросов. Например, в шафиитском мазхабе имеется вопрос «*вилайат-е иджбар*»[1], в ханафитском мазхабе имеются такие проблемы, как «*када биль-батыль*» и «*икрах*»[2].

Следование какому-либо из мазхабов в ошибочных вопросах, конечно, является грехом. Чистота ислама и священный статус шариата требуют признания этого.

Таково мое отношение к любому из мазхабов в исламе. Исламский шариат, иными словами, священные аяты Благородного Корана и Сунна великого Законодателя, являющиеся источником всех мазхабов, сами по себе превыше любого из мазхабов по отдельности, и в целом. Исламский шариат крайне широк в своих основах и источниках.

Наш исламский шариат совершенен благодаря священным аятам благородного Корана и Сунне пророка. Он сохранился, не потеряв ни крупицы. К нему не пристало ничего извне, поэтому он остался пречистым.

Мазхабы, может быть, и нуждаются в переустройстве и усовершенствовании, но наш ислам ни с какой стороны не нуждается в реформах.

В одно время христианство нуждалось в обновителях веры и реформаторах. Было время, когда в христианском мире возникли протестанты, появились лютеры[3]. Но мы, и наш ислам, да возблагодарим Всевышнего, не нуждается ни в лютерах, ни в реформаторах.

Возможно, быть лютером, быть реформатором и является честью. Вполне может быть, что люди очень стремятся достичь такой чести. Но наш ислам не нуждается ни в славе лютерства, ни в величии реформаторства. Ради могущества

---

[1] вилайат-е иджбар – область, в которой допустимо принуждение.

[2] када биль-батыль – решение, принятое на основании ложной посылки; икрах – необоснованное принуждение.

[3] лютеры – подразумевается Мартин Лютер (1483–1546) – немецкий священник, теолог, писатель; наиболее известен как ключевая фигура протестантской Реформации и как эпоним лютеранства.

ислама и его чистоты я жертвую такой высокой честью, я отказываюсь от таких имен.

Я совершенно свободно критикую мазхабы. Я преклоняюсь перед священным исламом, который является величайшим Божьим законом…

После отделения друг от друга мазхабов и священного шариата следует: 1) свободно критиковать мазхабы и 2) преклоняться перед чудесным шариатом.

Коль наше мышление захвачено двумя видами порока, то нам, конечно же, необходимо будет принять обе этих позиции.

Одним из упомянутых двух пороков является такая напасть, как таклид. До сегодняшнего дня в мире ислама господствовало убеждение, что «нужно следовать одному из прежних мазхабов». Это бедствие ослепило наше мышление, усложнило наше социальное положение и жизнь. В итоге, наш чудесный шариат оказался вне нашего внимания.

Пока не будет принята первая позиция, т.е. пока наш разум и мысль не освободятся от болезни таклида, у нас всегда будет сложная общественная ситуация, священный шариат всегда будет оставаться вне нашего внимания.

Второй, более страшный порок, захвативший наши умы – это чума неотаклида (*яңа тәкълид*). В то время, как первый таклид выражается в жертвовании шариатом во время молитв, возносимых в рамках освящаемых мазхабов, эта новая форма таклида стала выражаться в игнорировании ислама и национальных интересов в восхищении перед величием Запада, его политическим могуществом, и, как следствие, уничижении себя перед ним. Прежний таклид, навязанный нам силой религии, превратился в нашу привычку и стал нашей природой. Именно по этой причине неотаклид так легко завоевал наши умы и души. Причины такого положения очевидны.

Некоторые турецкие писатели, воспринимая ислам как подобие протестантизма, возникшего в христианском мире, провозгласили Великого законодателя и Благородного пророка Мухаммада (ﷺ) реформатором, подобным Мартину Лютеру.

Выходит, что самое важное в исламе – это его протестантская сущность! Выходит, что величайшим достоинством Великого законодателя является то, что он, по сути своей, подобен Лютеру!

Два этих предложения я прочитал на страницах одного из произведений Джелала Нури[1], напечатанных в этом году. Краткое их содержание таково: «Мухаммад взял иудейский и христианский Закон Божий и реформировал их. Реформированный иудаизм и христианство стали называться исламом. Так, Мухаммад еще в VII веке наилучшим образом произвел ту реформацию, которая произошла в XVI веке стараниями Мартина Лютера».

Похожие мысли я встречал неоднократно в произведениях других турецких авторов. В конце концов из уст самого ученого турецкого писателя я услышал следующие слова: «Ислам – это, по сути, протестантизм».

Если толковать их тем или иным образом, то такие слова, может быть, и верны. Но с духовной позиции такие слова являются большим позором. Поиск всего хорошего на путях подражания иноземному и чуждому есть самая низкая подлость. В высшей степени позорно называть ислам протестантизмом, а Великого законодателя – Лютером.

Если бы в наших мозгах существовала самостоятельная мысль, а в душах была бы мощь ислама, или если бы в наших сердцах имелся бы хоть слабый признак национальной силы, то мы не пали бы в пучину такого великого унижения и позора. Мы бы не радовались унизительным невежественным и глупым заявлениям о том, что Мухаммад был Лютером седьмого века, был педагогом, психологом. Почему в то время, когда западный мир так сильно прогрессировал в силе и могуществе, наши мысли и души оказались полностью зах-

---

[1] Джелал Нури (Мехмет Джелал Нури Илери; 1881–1938) – турецкий писатель, философ, политик; автор многочисленных трудов, из которых Бигиев подразумевает книгу «Hatem'ül Enbiya» (Печать пророков).

ваченными страшной болезнью самоуничижения и беспрекословного подражания всему чуждому?

Я взирал на наше плачевное положение с отвращением и унынием. И предложил вторую меру, надеясь, что она излечит эту болезнь. Эта мера заключается в том, чтобы почитать в качестве священных понятий ислам, шариат и нашу нацию.

Мы можем быть очарованы и пленены западными науками, техникой и промышленностью. Нам, конечно же, необходимо подражать Западу во всех этих священных вещах или двигаться вместе с ним. Однако могущество ислама, святость нашего шариата в наших глазах несравненно выше. Признаем, что западные законы, право и юридические науки хороши. Но если мы считаем, что в сегодняшнем мире мусульманские правовые мазхабы потеряли свою актуальность, то грех не в них, а только лишь в нас самих.

Признаем, что пока мы избавились от такого порока как таклид древним мазхабам. Признаем также, что сегодня мы вдохнули воздуха свободы. Надо думать, что после этого нам совершенно не пристало униженно следовать за иноземцами в мышлении и движении. Надо думать, что теперь для нас совершенно неприемлемо искать все хорошее и полезное только лишь в подражательстве. Нам необходимо и свободомыслие, и святость ислама. Поэтому я критикую мазхабы и прославляю ислам.

Итак, я предложил две основы нашего священного шариата, которые возможно использовать после разделения, проведенного между правовыми мазхабами и священным шариатом: 1) способность и возможность свободной критики мазхабов и, 2) почитание и уважение нашего чудесного шариата.

Если учесть, что наша мысль поражена двумя болезнями, двумя пороками, то нам, конечно же, необходимо принять каждую из этих двух основ.

Одним из названных пороков является практика безоговорочного следования предписаниям древних религиозных авторитетов. Так, в мире ислама до сегодняшнего дня сущест-

вовала вера в то, что таклид одному из древних мазхабов является нашим долгом.

Эта унизительная практика таклида ослепила нашу мысль и, усугубив наше собственное состояние и состояние нашего общества и жизни в целом. В итоге, все это привело к тому, что наш чудесный шариат был вынесен за рамки внимания.

До тех пор, пока не будет принята первая основа, т.е. пока наш разум не освободится от традиции унизительного таклида, до тех пор наше общественное состояние будет тяжелым и священный шариат будет оставаться вне границ нашего внимания.

Нет сомнения в том, что принятие этой первой основы совершенно необходимо во имя достоинства ислама, и могущества мусульманской уммы. Ни коим образом недопустимо приносить в жертву ислам и шариат в угоду фантазиям о якобы «почитании» одного из мазхабов.

Другим, и, возможно, даже более тяжким пороком, поразившим нашу мысль, является позорный и унизительный неотаклид.

Если традиционный таклид представлял собой жертвование шариатом в силу преклонения перед святостью мазхабов, то упомянутый современный таклид стал отказом от ислама и принесением в жертву мусульманской уммы на фоне собственного самоуничижения, возникшего из-за очарования величием западной цивилизации и ее политическими достижениями. Прежний таклид, который навязывался нам силой религии, стал нашей привычкой и природой. Именно поэтому неотаклид так легко проник в наше мышление и душу, полностью захватив их. Причины этого положения совершенно очевидны:

Мы были слабы во всех отношениях. Боль тяжких ударов и воздействие крайне поучительных примеров разбудили нас. Глаза наши были ослеплены блеском западной цивилизации, на фоне прогресса Запада наши мысли пришли в замешательство. Мы были словно пленены его силой и мощью. Мы были поражены, мы впали в безумие. Мы были очарованы

блеском западной мишуры. Любое явление и любое движение, имевшее там место, стало для нас священным. Мы отвергли все свое и возненавидели все, что у нас было. Самое дорогое наше достояние и самые лучшие стороны нашего бытия полностью утратили в наших глазах свой священный статус. И хотя мы не смогли последовать за Западом в том, что действительно было полезным, мы, тем не менее, стали подражать ему в большинстве не имеющих ценности и значимости вещах. Мы не смогли перенять чего-то нового, но потеряли все то, что было у нас самих святого.

Страсть к неотаклиду не ограничилась лишь нашим общественным состоянием. Мы стали подражать Западу и своим мышлением, и своей историей. Мы придали истории ислама тот же вид, какой имела история христианства. Так в мире ислама возникли идеи религиозной реформации. В головах некоторых наших мыслителей возникли мысли о Реформации по западному образцу. Они словно хотели, чтобы и ислам не был бы лишен чести иметь свое движение, подобное движению Мартина Лютера, которое стало гордостью христианства. Но дело не ограничилось только этим. Некоторые турецкие писатели стали считать ислам чем-то подобным протестантизму, возникшему в христианском мире, и провозгласили Великого законодателя – Благородного пророка Мухаммада (да будет мир ему и божье благословение), реформатором, подобным Мартину Лютеру. Таким образом получалось, что самое важное в исламе это его протестантская сущность! Получалось, что главное достоинство Великого законодателя в том, что он был подобен Лютеру!

Эти два предложения я прочитал в изданной в этом году в Стамбуле книге Джелала Нури на 38–39-й страницах. Вот краткое их содержание:

«Мухаммад взял иудейский и христианский Закон Божий и реформировал его. Реформированное иудейство и христианство стало называться Исламом. Таким образом, Мухаммад совершил Реформацию лучшую, чем та, которую произвел в XVI веке Мартин Лютер».

Слова, близкие по смыслу упомянутым, я несколько раз встречал на страницах турецких книг и до этого. Наконец, один из самых знающих турецких писателей заявил прямо: «Ислам по сути своей является протестантизмом».

Может быть такие высказывания и верны, если объяснить и растолковать их. Но по духу своему они являются крайне унизительными и позорными. Поиск всего хорошего на путях подражания иноземцам является отвратительной низостью. Позорно и недостойно прикреплять к исламу титул протестантизма, а Великому законодателю «оказывать честь» быть Лютером.

Если бы в наших головах была бы мысль о независимости, а в нашем духе – сила и мощь ислама, или если бы в наших душах остался бы хоть след национального достоинства, то мы не впали бы в такое унижение и позор. Мы не радовались бы позорным словам и глупым заявлениям, что Мухаммад был Лютером седьмого века, что он был педагогом, что он был психологом.

Почему же на фоне такого впечатляющего прогресса Запада в могуществе наша мысль и дух оказались настолько полно захваченными ужасными болезнью унижения, болезнью таклида?

Я взирал на это наше состояние глазами, полными недоумения и горького сожаления. В надежде найти средство излечения этой болезни я предложил вторую основу. Она заключается в священопочитании ислама, шариата и мусульманской уммы.

Мы можем быть очарованы науками и промышленностью западного мира. Нам, конечно же, необходимо следовать за Западом, подражать ему во всех этих священных вещах или двигаться и развиваться вместе с западным миром. Но святость ислама, священность нашего Закона Божьего – шариата, на наш взгляд, выше всего этого. Признаем, что западные законы и право прекрасны. Однако, по моему мнению, если сегодня западный мир не признает мусульманские мазхабы, то грех не в них, а в нас самих.

Допустим, что мы сегодня избавились от бедствия таклида, от бездумного подражания древним мазхзабам и вдохнули воздуха свободы. После всего этого нам не пристало позорно и униженно подражать в мышлении и развитии чуждым традициям. Надо думать, что неразумно искать все хорошее и благое только на путях подражания кому бы то ни было.

Нам необходимо свободомыслие и священный статус ислама. Я критикую мазхабы и провозглашаю святость ислама.

# «Почему Запад когда прогрессировал, а мир Ислама шел к упадку?»[1]

В настоящее время между западным и исламским миром существует большая разница. Один из этих миров утвердился на троне господства в [международной] политике и всевластия и намерен никогда больше не покидать его. Он захватил все имеющиеся на земле природные кладовые и присвоил себе все могущество и силу. Второй из этих миров, подобно невольнику, лишен возможности участовать в [международной] политической жизни, стал неспособным управлять своими делами по своему усмотрению, насильно лишен возможности расходовать по своему желанию свое имущество в своем же жилище. Подобно рабу, он повсеместно оказался под чуждым управлением.

Конечно же, у этого явного различия состояний есть своя причина. Второстепенные причины этого могут быть сколь угодно разными, но главная причина, тем не менее, всего одна. Только показать эту главную причину открыто очень трудно. И вообще, определение истинных причин исторических событий и общественных состояний является трудным делом. Западный мир проявил старание и усердие. Силой наук и просвещения он подчинил себе и природу, и все народы земли. В то же время мир Ислама не развивался, он бездельничал и оставался в невежестве. Поэтому, когда западный мир прогрессировал, мир Ислама катился вниз.

Является ли это главной причиной? Если да, то в чем причина того, что один усердно трудился, а другой бездельничал? Наука и просвещение стали развиваться в западном мире приблизительно в конце восьмого века. Но почему этот

[1] Источник: Муса әфәнде Бигиев. Халык назарына берничә мәсьәлә. Казан: Электро-Типография «Умид», 1912. Б. 33–39. (пер. с татаро-османского наш).

начавшийся так давно процесс на протяжении веков не мог набрать силу? Почему он, однажды начавшись, все слабел и слабел? Почему до начала XVI века не могло оживиться просвещение? Почему не обрели широты и размаха признаки и достижения прогресса?

В начале XVI в. благодаря благотворному влиянию начавшейся в Германии Реформации мысль и разум западного мира были освобождены из-под гнета духовенства. Науки и просвещение смогли вздохнуть свободно.

Реформация, которая возникла на почве небольших [религиозных] проблем, очень быстро усилилась, расширилась и дала западному миру важные блага: человек добился [признания] своей человеческой природы, разум добился [признания] своего первенства и приоритета, самостоятельности, свободы и принятия его как практически значимой силы. После этого человеческий разум стал быстро осваивать бескрайние просторы материального мира и открывать все новые кладовые и тайны природы. Творческие потенции и практические возможности людей освободились из удушающих объятий католицизма. Человек стал усердно двигаться по пути наук и практической деятельности. Поэтому в последующие века после Реформации так легко проявились прогрессивные явления, которые были невозможны в эпоху, когда разум был заперт в стенах церкви и руках духовенства.

Благодаря освобождению разума из угнетающих пут церкви западный мир ступил на путь прогресса. В то время [учащиеся] мусульманских медресе были заняты чтением толкований и комментариев к каламическим [догматическое богословие] книгам. Мусульманские богословы были увлечены написанием [таких] толкований и гордились этим. В то время разум и мысль мусульман были пленниками в руках факихов [мусульманских правотворцев], слепо подражавших установлениям древних авторитетных богословов и возгордившихся мутакаллимов [догматистов]. Видимо, именно из-за влияния застоя, поразившего головы всех мусульман, мир Ислама лишился жизни, застыл без движения!

Дни, когда на арену истории ступил великий реформатор Мартин Лютер, совпали со временем, когда Османским государством правил величайший из всех правителей этой страны Сулейман Кануни [Справедливый]. Это значит, что христианские государства тогда были слабее исламской державы. Но благодаря деятельности великого обновителя Мартина Лютера христианский мир ступил на путь прогресса, а мир Ислама, под влиянием исповедовавших каламические догмы шейх-уль-исламов [официальных духовных чиновников], таких, например, как Ибн Кямал, Абу ас-Сугуд, был низвергнут в пропасть застоя. Иными словами, мир ислама покатился назад по причине того, что оказался плененным и скованным разум.

Мусульманский философ, слепой поэт Абу аль-Аля [аль-Маарри], предупреждая об этом ужасном историческом будущем, словно истинно пророческим языком писал в «Обязательности необязательного» [«аль-Лузумият»]:

*Они развивались, но мы дремали.*
*Когда мы катились назад, они трудились.*
*Конечно же, дороги прогресса проходят мимо*
*Наших лежбищ невежества*[1].

Если плененный разум лишается права свободно мыслить и выносить решения, то сковывается и практическая активность, деловитость. Когда человек поражается боленью безделья, то даже самые ничтожные вещи обязательно оказывают на него свое негативное влияние.

Наверное, поэтому идеи, рожденные в затхлых кельях дервишей и распространенные ими, проповеди, звучавшие с минбаров мечетей и всегда проклинавшие мирскую жизнь, взгляды аскетов и отшельников, всегда искавших счастье в нищете и лишениях, суфийская философия, везде ищущуая следы сатаны – смогли оказать влияние на страдавший в неволе разум мусульман.

Поэтому ум и тело исламского мира оказались без дела. Поэтому, когда западный мир развивался, мир Ислама катился

[1] подстрочный перевод с араб. наш.

вниз. Поэтому между западным и исламским миром возникла большая разница. Поэтому один добился чести лидерства, а другой погряз в отсталости и позоре.

Такова моя позиция в этом вопросе. Этот взгляд занял место в моем сердце благодаря размышлениям о политической и культурной истории Ислама. Этот мой взгляд окреп, благодаря чтению трудов ученых, которые писали о причинах сегодняшнего положения и мерах по их решению.

Подталкиваемый этой усилившейся в моей душе верой, я решил что-то делать. Все, что я написал, все, что сказал, все это делалось по указанию этой моей убежденности. Всем, что я говорил и писал, преследовал только одну цель: освобождение разума и мысли, разрушение преград, воздвигнутых мазхабами [правовыми школами Ислама и различными течениями теологической мысли], преодоление слабости нашей воли и [приземленности] желаний. Иными словами, моей единственной целью было освобождение разума и преодоление приземленности наших устремлений. Ибо главной причиной современного положения мира Ислама является скованность разума и слабость воли.

Я без всяких сомнений и колебаний верю в то, что Ислам – истинная религия, что он величественен и священен. По моему мнению, учение такой священной религии как Ислам никаким образом не может быть ограничено узкими рамками мелких мазхабов. Ограничение Ислама такими тесными границами, несомненно, является недостатком. В этом вопросе я, конечно же, отвергаю мазхабы.

В Исламе разум не был ограничен, он был свободен и почитаем, как величайший Божий дар. В мусульманских государствах свобода разума и мысли были первичными, это было естественным правом. В эпоху наших древних священных праведных предков не было традиции насильного навязывания [верующим] одного из мазхабов. Такое бедствие как безумие и дикость, выражавшееся в ограничении [роли и места] разума, сужении его возможностей, враждебном отношении к науке и просвещению, в проклятии мыслителей, обвинении

всякой свободы в безбожии, судя по всему, проникло в учения мутакаллимов в качестве наследия ужасных религиозных судилищ инквизиции, которая в течение семи веков царствовала в католическом мире. Ибо такое безумие, такая дикость совершенно не могут возникнуть из духа Ислама.

Варварство судов инквизиции легко проникли в отравленную [греческой] диалектикой кровь мутакаллимов и их сердца, горевшие желанием принуждать, запугивать и преследовать. Мутакаллимы, именем религии, заставили принять эти дикости в мире Ислама. Эти бедствия, претворенные в жизнь и внедренные в практику именем религии, укоренились в головах и сердцах. По моему мнению, именно так были пленены разум, воля и [духовные] потенции мусульман. Эта несвобода основной стала причиной всех последующих смут и бедствий.

Освобождение из плена есть главное и единственное условие для оздоровления. Если не будут освобождены разум и воля, все иные способы и меры будут бесполезны и не дадут результатов.

Поэтому я присоединился к течению мысли, провозглашающему свободомыслие. Я стал отвергать ограничения, искуственно воздвигнутые и намеренно навязанные представителями мазхабов. По многим вопросам я смело выступил против приверженцев мазхабов. Это делалось не для того, чтобы обвинить древних великих ученых в допущенных ошибках, а для того, чтобы показать мою твердую веру и убежденность в свободе разума и мысли, в широте Ислама и его величии.

Я счел этот образ действий и это кредо обязательным для себя. Это казалось мне началом, преддверием нашего освобождения. Это был единственный способ действий, который наиболее полно соответствовал нашим сегодняшним задачам и нуждам. Не было сомнений в том, что по отношению к будущему он не несет вреда, но только пользу.

Остерегаясь, что литературно-художественные произведения, которые я мог бы написать силой своего художест-

венно-литературного дара, мысли, которые я мог произвести работой моего мозга, чувства, которые могли излиться из моей души, конечно же, могут быть неглубокими, я избегал написания литературных сочинений. Внушение в души читателей мелких и банальных идей, низких чувств, по моему мнению, стало бы отравлением их чистых сердец и не принесло бы пользы.

Желая разрушить утвержденные мазхабами установления, ограничивающие разум, волю и мышление человека, я провозгласил и показал росийским мусульманам довольно много проблем и вопросов. Конечно же цель моя была благой. Если бы я достиг этой цели, то ее благо и польза, конечно, были бы велики. Все эти вопросы были в той или иной степени важны и актуальны. Они были важны тем, что могли улучшить наше общественное положение, могли возвысить учение Ислама и [восстановить] его величие. В них невозможно было найти какой-нибудь вред, ибо каждая из тех проблем, вне всякого сомнения, стояла выше амурных рассказов и любовных романов и, в общем, всех произведений эротического толка.

Заканчивая, я решил представить мое отношение к нашей современной литературе.

На мой взгляд, язык нашей литературы не совсем правильный. В литературных произведениях в большом количесвте обнаруживаются грамматические, синтаксические и стилистические ошибки. Если эти огрехи, возникшие из-за беспечности современных наших литераторов, пристанут к нашему языку, то язык, развивавшийся в руках наших предков, станет деградировать. Ветви общетюркского древа, произрастающие из одного корня, никогда не смогут дать плодов единства, а дальнейшее движение вперед будет все больше и больше разъединять [тюркские народы].

По моему мнению тенденции нашей современной литературы не отвечают нашим нуждам. Амурные рассказы, любовные романы и переводы художественных произведений других народов и вообще, ни одно из произведений, написанных в духе эротизма (что отдаляет их от серьезности и приб-

лижает к бесстыдству), совершенно не соответствуют нашим потребностям.

В западном мире имеется все. Если во время нашей всесторонней слабости во всех отношениях, когда не можем удовлетворить ни одной из своих нужд, мы будем следовать за развлечениями и праздностью Запада и не будем прислушиваться и присматриваться к настораживающим явлениям и вещам, провозглашаемым в западном мире тревожным языком «горького опыта», и если будем смотреть сквозь пальцы на причины постоянно растущей преступности, порочности, бесстыдства, социальных болезней, то наше будущее на обрадует нас.

Требованиям нашего современного состояния больше соответствует обогащение нашей литературы серьезными произведениями, усвоением собственными силами только необходимых нам научно-технических и промышленных достижений Запада. Сейчас необходимо, хотя бы на время отложив в сторону западные игры, развлечения и праздные романы, воспитывать наших детей в духе деловитости, приучать их к торговле, коммерции и сельскохозяйственному труду.

Я считаю, что иного пути для нашего спасения и прогресса нет.

# «Могъҗиза»[1]

Коръән кәримнең бәянына күрә, әүвәлге өммәтләрдә, нәбилекнең дәлиле буларак, могъҗизалар да күрсәтелә иде. Кешедә иман хис-тойгылар белән, вөҗдан белән, йөрәк белән хасил була. Иманда вөҗданның өлеше, вөҗданның катнашы акылның өлешеннән, һәрхәлдә, зуррак. Шуңа күрә булса кирәк, илаһи кайгырту кешеләрнең хиссиятләренә, вөҗданнарына иң көчле тәэсир ясый алган могъҗизаларны нәбилекнең иң әүвәлге дәлилләре иткән.

Могъҗизалар әхлакның төрлелегенә күрә төрле була. Шуңа күрә, көч вә гайрәт пәйгамбәре Муса, галәйһис-саләт вәс-сәлам, хәзрәтләренең могъҗизалары куркыту, дәһшәтләндерү могъҗизалары булып, шәфкать пәйгамбәре Гайсә, галәйһис-саләт вәс-сәлам, хәзрәтләренең могъҗизалары үлеләрнең җаннарын кире кайтару, сукырларга сәламәт күзләр бирү, хәстәләрне аякка бастыру, күктән аш индерү кебек мәрхәмәт могъҗизалары иде.

Хакыйкатьләрен аңлау өчен могъҗиза төшенчәсен бираз тикшерүгә дучар итик:

1) Могъҗиза кешеләр ия булган хис итү әгъзаларының берсе белән сизелә алган вакыйга булырга тиеш.

Сизелмәгән вакыйга, никадәр зур, никадәр гайре-табигый булса да, һичнинди сурәттә могъҗиза булмый. Шуңа күрә, «исраъ»[2] кебек гадәттән тыш зур вакыйга Коръән кәримдә Шаригъ хәким белән булган бер вакыйга буларак хикәят ителсә дә, расүллекнең, нәбилекнең дәлиле буларак тапшырылмаган. Чөнки ул зур вакыйганы ул чакта һичбер кеше үз

---

[1] Муса Җаруллаһ. Бөек мәүзугларда уфак фикерләр. СПб.: Типография М-А. Максутова, 1914. Б.70–92. (Өзек татар теленә тәрҗемә ителеп бирелә).

[2] исраъ – Мөхәммәт пәйгамбәрнең Мәккәдән Кодестәге Мәсҗид әл-Әксага төнге сәфәре.

күзе белән күрмәгән. Бәлки Расүл әминнең[1] сүзенә, Коръән кәримнең айәтләренә иман итү бәрәкәте белән, «исраъ» вакыйгасына сәхабәләрнең барысы да инанган.

2) Могъҗиза – гадәттән тыш вакыйгадыр.

Ягъни: безгә мәгълүм булган куәтләрнең, кануннарның һичберсенә иярмәү, буйсынмау. Могъҗиза вакыйгасы табигый кануннарга, табигый куәтләргә иярмәсә дә, могъҗиза ул кануннарны, ул куәтләрне гамәлдән чыгармый. Бәлки тагын да зуррак, тагын да көчлерәк кануннарның тәэсирләре астында, кешеләргә таныш булган табигый куәтләрнең чагылышлары күренмичә юкка чыгалар. Нибары шул кадәрдер.

Югарыда 4 нче, 5 нче, 6 нчы номерлар белән билгеләнгән уйлануларыбызда бәян иткән идек ки: табигый куәтләр куәт булсалар да, илаһи куәт алардан өстендер; табигый кануннар даими һәм өзлексез булса да, илаһи ихтыяр һәрчак аларның һәммәсеннән югары тора.

Биредә табигать дөньясыннан бер шаһит таба алабыз:

Мәсәлән, билгеле бер авырлыкка ия булган агач үскәндә, аңа салынган үсү куәте белән югарыга сузыла. Биредә җазибият[2] кануны юкка чыкмый. Бәлки югарыга сузылу кануны җазибият канунынннан өстен чыга, җазибиятнең галәмәте күренми.

Мисал өчен, авырлыкка ия булган бер ташның кеше кулы белән өскә таба атылуын күз алдыбызга китерик. Таш югарыга оча. Биредә җазибият кануны юкка чыкмады, гамәлдән чыгарылмады, бәлки тышкы тәэсирләрнең берсенә җиңелеп, аның галәмәте күренә алмады.

3) Табигать кануннарына каршы килмәү.

Мәсәлән, кызулыгы булган ялкын пешерер, кешенең тәне утта янар. Бу, әйтик, бер канундыр. Кызулыгы булган утта тәннең янмавы моңа каршы килә. Коръән кәримдә искә алын-

---

[1] Расүл Әмин – Турылыклы Расүл, ягъни, Аллаһ илчесе; Мөхәммәт пәйгамбәрне олылап искә алу шәкеле.

[2] җазибият (гарәп.) – авырлыкка ия булган матди җисемнәрнең бер-берсенә тартылулары, гравитация.

ган Хәлил кыйссасында[1] исә, قُلْنَا يَا نَارُ كُونِي بَرْدًا وَسَلَامًا عَلَى إِبْرَاهِيمِ [2] дигән илаһи хитаб[3] ялкыннан кызулыкны алган, Хәлилнең бәдәне ул салкын утта исән-имин калган.

Фиргавен сихерчеләре турындагы кыйссада, Муса, галәйһис-саләт вәс-сәлам, таягына җан биреп, ул җанлы таяктан сихерчеләрнең таякларын йоттыруы тагын да зуррак бөек могъҗиза була алса да, илаһи ирадә[4] андый могъҗизаны сайлап алмаган, чөнки агач кисәгенең тере булуы табигать канунына каршы килә. Бәлки агач кисәге башта аждаһа сурәтенә әверелеп, соңыннан илаһи ирадәнең әмере белән шул җанварга җан өрелгән.

Гайсә, галәйһис-сәламнең, мәетләрне терелтү кебек могъҗизалары да шундый: черек бәдәндә хәят булуы табигать кануннарына каршы килә. Шуңа күрә, терелтеләчәк кешенең гәүдәсе кодрәт кулы белән сау бәдән сурәтенә китерелә дә, соңыннан аның җаны кайтарыла.

Дәҗҗалның фетнәләре белән нәбиләрнең могъҗизалары арасында булган аермаларның бере шул. Дәҗҗалның фетнәләре бәлки гаять олы вакыйгалардыр. Ләкин табигатьнең кануннарына каршы килүләре аркасында, алар Аллаһның катнашуына кайтарып калдырыла алмыйлар. Чөнки Хәким мотлак[5] үзенең илаһи хикмәте белән урнаштырган кануннарын һичбер вакыт юкка чыгармый.

Дәҗҗалның фетнәләре белән нәбиләрнең могъҗизалары арасында охшашлыкның ныклыгы хакындагы уйларымны «Озын көннәрдә рузә» исемле китапның 70 нче сәхифәсендә бәян кыйлган идем. Мәсьәлә диннәрнең нигезенә кагылышлы булуы аркасында, гаять мөһим иде, ләкин мәсьәләләрнең

---

[1] Хәлил кыйссасы – Коръәннең Ибраһим пәйгамбәр турында хикәяләве.

[2] «Без әйттек: «Әй, ялкын! Ибраһим өчен салкынчалык һәм иминлек бул!» – дидек» (Коръән, 21:69).

[3] илаһи хитаб – илаһи мөрәҗәгать, илаһи әмер; Аллаһның дәшүе, кушуы.

[4] илаһи ирадә – илаһи теләк, илаһи ихтыяр, Аллаһның теләге.

[5] Хәким мотлак – белеме, хикмәте белән һәрнәрсәне үзенә сыйдырган; хикмәтнең иң югары дәрәҗәсенә ия булган.

әһәмиятенә күрә, әһле гыйлемнең олы игътибарларын җәлеп итү безнең дөньяда гаять авырдыр.

4) Могъҗиза бары тик Аллаһның теләге белән, кодрәте белән арадашчысыз вакыйг була[1].

Һәр могъҗиза Аллаһның мотлак кодрәтенә арадашчысыз барып тоташа. Дөрес, могъҗиза вакыйг булганда, табигый куәтләр, әлбәттә, юкка чыгарылмый, табигый кануннарга да могъҗиза каршы килми. Ләкин ул куәтләрне хәрәкәткә китергән иң бөек сәбәп Аллаһның илаһи теләге, мотлак кодрәте була. Могъҗиза вакыйг булганда, табигый куәтләр хезмәт күрсәтүче нигез буларак мәйданда булсалар, асыл тәэсир илаһи кодрәтнең даирәсе була.

Мәсәлән, табигый куәтләрнең, табигый кануннарның тәэсире белән агач үсә, ди. Аның гади сурәттә, табигый сурәттә үсүе озын заман дәвамында, аз-азлап бара. Кешенең үсеп җитешүе дә шулай: мәни суы ана карынына иңә, шунда берничә ай кала, туа; соңыннан бер ел дәвамында «адәм» була. Бу ике вакыйга, гадәттә, озын заман дәвамында хасил була ала.

Ләкин фараз итик: бабабыз булган әүвәлге адәмне илаһи кодрәт бүгенге сурәте белән كُن فَيَكُونُ[2] кануны белән халык кыйлган ди. Бер секунд дигәндә адәмне бүгенге кыяфәтендә халык кыйлу вакыйгасы – хилкатьтә[3] могъҗиза булачак. Бу мисалда табигый кануннарның эзе, табигый куәтләрнең тәэсире юк. Югарыда 4 нче һәм 5 нче уйлануларда яздык: илаһи куәт табигый куәтләрдән өстендер: миллион еллык нәрсәләрне ул бер секунд дигәндә иҗат итә ала.

Хилкатьнең бу могъҗизасы ике юлның бере белән хасил була ала: 1) йә матдәләргә тагын да зуррак кабилият[4] биреп, куәтләрнең тәэсирләрен тизләтү, 2) яки «уникаль (*дәфгый*) хилкать илаһи куәтнең галәмәтедер»,– дип әйтмәк.

Бу ике очракның һәрберендә табигый куәтләр Аллаһның илаһи кодрәтенә буйсынган булалар. Алар юкка чыкмыйлар,

---

[1] вакыйг була – була, барлыкка килә; чынбарлыкка аша.

[2] «Бул! Һәм ул була» (Коръән, 3:47).

[3] хилкать – мәхлукъның табигате; тышкы кыяфәт, рәвеш; форма.

[4] кабилият – сәләтлелек, булдыклылык

ләкин илаһи куәт янәшәсендә аларның көче бик түбән гамәлдән булып кала.

«Дини тәдбирләр»нең 30 нчы сәхифәсендә мөхтәрәм мөәллиф әфәнденең каләме белән язылган тәэвилне без биредә кабул итә алабыз: ягъни فَإِذَا سَوَّيْتُهُ وَنَفَخْتُ فِيهِ مِن رُّوحِي فَقَعُواْ لَهُ سَاجِدِينَ؟[1], дигән илаһи хитаб табигый куәтләргә атап әйтелгән хитаб була ала. Кешенең илаһи кайгырту кулы белән тәсвия кыйлынган[2] җәсәденә[3] илаһи кодрәт илаһи рухны өреп кертсә, бөтен куәтләр үзләрен барлыкка китерүчеләргә дә, инсанда булган өлүһият гонсырларына[4] да буйсыныр, хезмәткә куелыр, сәҗдә кыйлыр.

Бу тәэвил, шөбһәсез, дөрестер; ләкин өлүһият хитабының хакыйкый мәганәсе дә, әлбәттә, күздә тотыла.

5) һәр могъҗизада матур бер максатның, таләп ителгән бер нәтиҗәнең булуы.

Нәбилекнең борһаны[5] булу, кешеләргә дөрес юнәлеш бирү, аларның рухларына, акылларына һәм әдәби, һәм иҗтимагый тәрбия бирү кебек кирәкле һәм матур максатларның могъҗизада булулары шарттыр.

Бу шартның бәрәкәте белән, нәбилек борһаны булган могъҗизалар дәҗҗал фетнәләреннән, гайре табигый эшләреннән өстен булуларын күрсәтәләр.

---

[1] «Мин аны көйләп аңа Үземнең рухымнан өргәч, сез иелеп аңа сәҗдә кыйлыгыз?» (Коръән, 15:29); биредә сорау билгесе куелуының сәбәбе аңлашылмый.

[2] тәсвия кыйлынган – көйләнгән; җиренә җиткерелгән; алдан ук уйланылган шәкелгә, рәвешкә китерелгән. Әлеге фигыль айәттә кулланылган (سَوَّيْتُهُ) сәввәйтү-һу (аны тәсвия кыйлдым) фигыленә бәйле булганына күрә, Адәмнең төзек бер хәлгә китерелүен белдерә.

[3] җәсәд – гәүдә.

[4] гонсыр – нинди дә булса матди җисемнең аерылгысыз өлеше; матди галәмнең элементлары; нәрсәнең дә булса табигате, асыл сыйфаты.

[5] борһан – катгый дәлил; кире кагыла алмый торган дәлил; теге яки бу карашның, фикернең дөреслеген кискен сурәттә раслый торган нәрсә.

Бу юл белән башкарылган анализ нәтиҗәсендә могъҗизаның хакыйкать булуы билгеләнә.

Могъҗизага килгәндә, ул: 1) сәламәт кешегә хас булган хис-тою әгъзалары ярдәме белән күзәтелер, 2) гадәттән тыш бер вакыйга булыр, 3) табигать кануннарына каршы килмәс, 4) нәбилек борһаны булыр, 5) нәбилек борһаны буларак арадашчысыз сурәттә илаһи кодрәт тәэсире белән барлыкка килер.

Димәк, могъҗизаларның биш гонсыры бар. Нинди дә булса бер вакыйгада шул биш гонсыр булса, ул вакыйга могъҗиза булыр.

Ләкин дәҗҗалның фетнәләре, гайре табигый эшләре могъҗиза түгел. Чөнки аларда 3 нче гонсыр белән 4 нче гонсыр юк. Дәҗҗалның гайре табигый гамәлләре кешеләргә файда китерә алган бер максатны тормышка ашыру юлында эшләнмәгән хәлдә, бәлки үзенә илаһилек кебек бер газаматның хас булуын дәгъва итү өчен башкарылалар.

Югарыда номерлар тәртибендә язылган мөкаддимәләрне, һәм һәр могъҗизада игътибар ителергә тиешле биш гонсыр турында дикъкать белән фикер йөртсәк, күренер ки: могъҗиза гадәттән тыш бер вакыйга булса да, ул табигать кануннарына, табигать фәннәрендә кабул ителгән асылларга һичбер ягы белән каршы килми.

1) Аллаһның бөеклеге, 2) илаһи теләкнең гамәлгә ашуы, 3) илаһи кодрәтнең җиңүе, 4) галәме вөҗүднең ниһаятьсез киңлеге, 5) кешелек дөньясының хәтерендә бүгенгә кадәр туплана алган гыйлемнәрнең табигать хәзинәләрендә әле һаман да кала килгән хакыйкатьләргә нисбәтән аз булуы – бу иң куәтле, иң нигезле биш чынбарлык, биш хакыйкать гаять ачык тел белән кешенең акылына могъҗизаларның мөмкин булуын ирештерә.

Бу хакыйкатьләрнең берсен булса да инкяр итү чамадан ашкан мәгърурият[1] булыр. Әгәр дә инкяр итү фән һәм гыйлем исеменнән булса, фән-гыйлемнең шәрәфенә карата да җинаять булыр. Әгәр дә безгә мәгълүм булмаган һәрбер ха-

[1] мәгърурият (гарәп.) – чиктән ашкан масаю, тәкәбберләнү.

кыйкатьне фән һәм гыйлем инкяр итсәләр иде, ул чакта табигать хәзинәләре дә кешенең хәтере кебек гаять тар һәм гаять кечкенә булып калыр иде.

الكون كالبحر ما غيضت غواربه
شيئا ومنه بنو الايام تغترف[1]

Тәрҗемәсе: *Галәме вөҗүд мохит диңгезе*[2] *кебектер – аның олы дулкыннары туктаусыз дәвам итә, шул мохиттән бөтен кешелек дөньясына насыйп булганы исә тик бер йотым гынадыр*.

Ягъни, кешелек дөньясының хәтерендәгеләр белән галәме вөҗүднең хәзинәләрен чагыштырсаң, араларындагы аерманың ифрат та олы булуы күренәчәк. Бу йөздән, кешелек дөньясы хәтереннән тыш булган хакыйкатьләрне инкяр итү – чиләктәге суга алданып, бөтен диңгезләрне инкяр итүгә тиң бер хәлдер.

Ләкин, нидәндер, кешедә кайчак мондый хәл күзәтелә. Кеше дин исеменнән гыйлемне инкяр итә, яки голүм вә мәгариф исеменнән диннәрне ялганга чыгара. Фәкать, мондый хәлләрдә гөнаһ диндә түгел, голүм белән мәгарифтә дә түгел; гөнаһ бары тик безнең күзебездә, күңелебездә, миебездәдер.

Инсаниятнең хәтерен галәме вөҗүднең хәзинәләре кадәр киң дип хыялланган мәгърурлар[3], яки галәме вөҗүдне кешенең баш мие кадәр кечкенә дип гөман итә торган җаһилләр – бары тик болар гына динне инкяр итә алалар.

Динне күз сукырлыгыннан, акыл күрлегеннән[4], калеб караңгылыгыннан гыйбарәт дип таныган, динне шундый хәлгә китергән «диндарлар», яки диннәренең ботланына[5] разый булган гафилләр – бары тик болар голүм вә мәгарифне инкяр итә алалар.

---

[1] Әбу әл-Галә әл-Мәгарриның «Лүзүмийәтү мә ләм йәлзәм» исемле поэмасыннан.

[2] Мохит диңгезе – Бөтендөнья океаны.

[3] мәгърур (гарәп.) – тәкәббер, масаючы.

[4] күр (төрек) – сукыр.

[5] ботлан (гарәп.) – ялган, ялгыш булу; хак булмау; файдасыз, буш.

Инсаният тарихында иман белән көфер һаман бил алышканнар, көрәшкәннәр, һаман шуны гамәл итәчәкләр. Ләкин дин белән голүм, илаһият[1] белән табигыять[2] үзара һичбер вакыт сугышмаганнар. Дөрес, динле берәү белән фәйләсүф, кәламчылар белән табигатьчеләр бере берсенә дошман була алалар. Әмма дин белән фәлсәфә, илаһият белән табигыйлык бере берсенә һичбер вакыт дошман булмас. Аларның һәммәсе һәрвакыт бер максатны күздә тоталар.

Югарыда бәян ителгән мәгънәдә могъҗизаларның мөмкин булуы заруридыр, акылга каршы килми дидек. Сәмави диннәрнең һәрбере могъҗизаларның барлыгына игътикад итәләр. Яһүдиятнең, нәсаранияттнең нигезләре могъҗизадыр. Өстәвенә, нәсаранияттә могъҗизалардан да өстен булган гадәттән тыш, гайре табигый серләр исемен йөрткән инанулар да бар.

Әһле ислам бертавыштан могъҗизаларның мөмкин булуына, барлыгына инанып, Нәбий-е ислам[3] Шаригъ кәбир[4] Мөхәммәд галәйһис-саләтү вәс-сәламү хәзрәтләре хакында да могъҗизаларның барлыгын дәгъва итсәләр дә, нәбилек дәлиле буларак могъҗиза төшенчәсе исламиятнең нигезләрендә исәпкә алынмый. Ягъни Нәбий-е ислам хәзрәтләренең тормышында могъҗизалар, әлбәттә, урын алган булсалар да, ләкин аларның һичберсе нәбилекнең чынлыгына, дөреслегенә, хакыйкыйлыгына дәлил, ислам диненең хакыйкыйлыгына нигез буларак вакыйг булмаганнар. Бәлки каршы чыгучыларның авызларын бераз гына булса да йомдыру өчен, яки бер илаһи бүләк рәвешендә күрсәтеләләр иде.

Шуңа күрә булса кирәк, нәбилекнең, рисаләтнең[5] хаклыгын раслый торган могъҗиза таләп иткән үзсүзлеләргә

[1] илаһият (гарәп.) – илаһилек; илаһи булу; Аллаһ турындагы гыйлем, теология.

[2] табигыят (гарәп.) – табигыйлык; табигать күренешләре.

[3] Нәбий-е ислам – ислам пәйгамбәре, ягъни Мөхәммәдﷺ.

[4] Шаригъ кәбир – Олуг шәригатьче, ягъни шәригать кануннарын тапшыручы.

[5] рисаләт – пәйгамбәрләр вә расүлләр аша кешеләргә атап юлланылган илаһи гыйлемнең иңдерелүе.

Коръән кәрим һәрвакыт, قُلْ سُبْحَانَ رَبِّي هَلْ كُنتُ إَلاَّ بَشَرًا رَّسُولاً[1] кебек, وَقَالُوا لَوْلَا أُنزِلَ عَلَيْهِ آيَاتٌ مِّن رَّبِّهِ قُلْ إِنَّمَا الْآيَاتُ عِندَ اللَّهِ وَإِنَّمَا أَنَا نَذِيرٌ مُّبِينٌ أَوَلَمْ يَكْفِهِمْ أَنَّا أَنزَلْنَا عَلَيْكَ الْكِتَابَ يُتْلَى عَلَيْهِمْ إِنَّ فِي ذَلِكَ لَرَحْمَةً وَذِكْرَى لِقَوْمٍ يُؤْمِنُونَ[2] кебек, قُلْ كَفَى بِاللَّهِ بَيْنِي وَبَيْنَكُمْ شَهِيدًا[3] кебек айәт кәримәләрдә дөреслеккә таба юнәлтеп җавап биргән. Ягъни: нөбүввәтнең, рисаләтнең әһәмиятләре могъҗизаларда түгел, бәлки, аның гыйлем бирүендә, дөрес юлны күрсәтүендәдер.

Нәбиләрнең иң мөкатдәс вазифалары иҗтимагый яшәеш хәлләрен ислях кыйлудыр, кешеләрне хаклык һәм әманәт рухлары белән тәрбия кыйлып, хакыйкать юлларына чыгарудыр.

Бер кеше иҗтимагый яшәешне яхшыртуга хезмәт итүче шәригатьне, тәгълиматны гамәлгә ашырса, үзенең илаһи куәте белән кешеләргә иҗтимагый рух биреп, аларны хаклык, пакьлек, тугрылык юлларына чыгарса, ул кеше нәби була, расүл була; куллары белән могъҗизалар кыйлса да, кыйлмаса да.

Нәбилекнең иң олы вазифасы шәригать булдыру, кешеләрне иҗтиһад, әманәт, тугрылык юлларына чыгару булганда, могъҗизалар рисаләтнең һәм нәбилекнең хакыйкыйлыгы дәлиле булып, әлбәттә, исәпләнә алмый. Бәлки нәбилекнең иң олы нигезе китап була, шәригать була. Шуңа күрә, Коръән кәрим болай дигән: أَوَلَمْ يَكْفِهِمْ أَنَّا أَنزَلْنَا عَلَيْكَ الْكِتَابَ يُتْلَى عَلَيْهِمْ[4].

Ягъни: нәбилекнең иң олы могъҗизасы, аның иң олы борһаны – хак һәм яхшы бер тәгълимат бәян итә торган китаптыр.

[1] «Әйт: «Мактаулар булсын Раббыма! Мин расүл буларак килгән бер кешедән кала тагын кем булыйм ди?» – диген» (Коръән, 17:93).

[2] «Андыйлар: «Синең Раббыңнан аңарга могъҗизалар җибәрелгән булса иде!» – дияләр. Әйт: «Дөреслектә, могъҗизалар алар Аллаһ карамагында, ә мин бары тик ачыктан-ачык кисәтүче генәмен»,– диген. Аларга атап укылып торган Китапны иңдерүебез җитмиме әллә аларга? Дөреслектә аңарда [Китапта] чын күңелдән инанучылар өчен мәрхәмәт һәм искәртүдер!» (Коръән, 29:50–51).

[3] «Әйт: «Минем белән сезнең арада шаһит буларак Аллаһның булуы да бик җиткән!» – диген» (Коръән, 29:50–52).

[4] «Аларга атап укылып торган Китапны иңдерүебез җитмиме әллә аларга?!» (Коръән, 29:51).

Шуңа күрә, исламиятнең иң олуг могъҗизасы Коръән кәрим булган:

قُل لَّئِنِ اجْتَمَعَتِ الإِنسُ وَالْجِنُّ عَلَى أَن يَأْتُواْ بِمِثْلِ هَـذَا الْقُرْآنِ لاَ يَأْتُونَ بِمِثْلِهِ وَلَوْ كَانَ بَعْضُهُمْ لِبَعْضٍ ظَهِيرًا[1].

Ягъни, илаһи хитаб ант итеп болай дигән: «Яхшы шәригать, хак тәгълимат җиһәте белән бу Коръән кебек бер китап булдыру өчен бөтен кешеләр, бөтен җеннәр җыелсалар да, бер берсенә ярдәм итә-итә көн-төн тырышсалар да, ахырда, әлбәттә, гаҗиз булачаклар, ягъни андый эшне башкарып чыга алмаячаклар».

Димәк, Коръән кәрим исламиятнең иң олуг могъҗизасыдыр. Ләкин Коръән кәримнең игъҗазы[2] бары тик бәлягать[3] кебек, яки гаъиб[4] турында хәбәр бирү кебек хосусыятләрдә генә түгел. Бәлки сукыр күзләрне, саңрау колакларны, капланган күңелләрне ачып, бөтен инсаният галәменә рух биргән, тугры юл күрсәткән хак тәгълимат, гүзәл шәригать булуындадыр.

لَقَدْ مَنَّ اللّهُ عَلَى الْمُؤمِنِينَ إِذْ بَعَثَ فِيهِمْ رَسُولاً مِّنْ أَنفُسِهِمْ يَتْلُو عَلَيْهِمْ آيَاتِهِ
وَيُزَكِّيهِمْ وَيُعَلِّمُهُمُ الْكِتَابَ وَالْحِكْمَةَ وَإِن كَانُواْ مِن قَبْلُ لَفِي ضَلالٍ مُّبِينٍ[4]
وَمَا أَرْسَلْنَاكَ إِلَّا رَحْمَةً لِّلْعَالَمِينَ[5]

Бу ике айәт кәримәдә исламиятнең бөтен әһәмиятләре, яки аларның иң олылары җыелган. Безгә игъҗаз дигән нәрсәне биреләрдә эзләргә кирәк. «Тәлхыйс»ләр[5] кебек китапларда

---

[1] «Әгәр кешеләр һәм җеннәр шушы Коръәнгә охшаш булган бер нәрсә булдыру өчен бергәләшсәләр дә, аңа охшаш булган бер нәрсәне, гәрчә үзара ярдәмләшсәләр дә, булдыра алмаячаклар» (Коръән, 17:88).

[2] игъҗаз – кабатланмас бер нәрсә булу, могъҗизавилек; уникальлек. Әлеге төшенчә Коръәнгә карата кулланыла һәм аның Аллаһтан иңгән нотык, китап булуын раслый торган сыйфатларын белдерә.

[3] бәлягать – сөйләм һәм язма телнең матурлыгы, төзеклеге, бәян ителәсе фикерне җиткерүдә камиллеге.

[4] гаъиб – адәм баласының тышкы дөньяны танып белү өчен яраклы әгъзалары белән танып белеп булмаган яшерен нәрсәләр.

[5] «Тәлхыйс» (тулы исеме: «Тәлхыйс әл-Мифтах») – Әбу Йагъкуб әс-Сәкькяи (1299 ваф.) исемле галимнең гарәп теле грамматикасына һәм бәлягатенә багышланган «Мифтах әл-голүм» исемле

телгә алынган игъҗазлар белән генә канәгатьләнү килешә торган эш түгел иде.

***

Нәбинең хакыйкый булуына ачык дәлил буларак могъҗиза ислам дине карашында игътибарга лаеклы бер нәрсә түгел, дигән идек. Ләкин исламияттә гадәти мәгънәдә могъҗизалар бар иде. Фәкать, аларның әһәмиятләре нәбилекнең дәлиле буларак түгел, бәлки башка нәрсәдә иде. Мәсәлән, «Сөрәка хәдисәсе»ндәге[1] могъҗиза зарардан котылу өчен иде; [пәйгамбәрнең] пакь бармакларыннан аккан су вакыйгасы да [кешеләрнең] хаҗәтләрен канәгатьләндерү өчен иде.

Нәбилек дәлиле рәвешендә булмаса да, исламияттә урын алган иң олы гадәттән тыш вакыйгаларның берсе, әлбәттә, «исраъ» вакыйгасыдыр. Ягъни бер мизгел эчендә Кәгъбәдән Мәсҗид Әкъсага[2] барып кайту вакыйгасыдыр.

Гадәттән тыш бу «исраъ» вакыйгасы Коръән кәримдә سُبْحَانَ الَّذِي أَسْرَى بِعَبْدِهِ لَيْلاً مِّنَ الْمَسْجِدِ الْحَرَامِ إِلَى الْمَسْجِدِ الأَقْصَى الَّذِي بَارَكْنَا حَوْلَهُ لِنُرِيَهُ مِنْ آيَاتِنَا إِنَّهُ هُوَ السَّمِيعُ البَصِير[3], дигән айәт кәримәсенең катгый хөкеменә күрә, әлбәттә, [пәйгамбәрнең] уяу хәлендә иде, әлбәттә, җисмани, ягъни гәүдә хәлендә иде.

---

әсәренә карата Хатыйп әл-Кәзвини (1388 ваф.) исемле галимнең каләме белән язылган шәрех күздә тотыла.

[1] «Сөрәка хәдисәсе» дигәндә, мөгаен, пәйгамбәр галәйһис-сәламнең аны үтерергә килгән мөшрикләрдән могъҗизалы рәвештә, ягъни дошманнарының күзләренә күренмичә (сөрәка – (سراقه өеннән чыгып китеп котылуы күздә тотыла булса кирәк.).

[2] Мәсҗид Әкъса (Ерак Мәчет) – Дар-әс-сәламдә (Иерусалимда) Куббәт әс-Сәхра мәчете янында урнашкан мәчетнең исеме.

[3] «Айәтләребезнең кайберләрен үзенә күрсәтер өчен, төнлә бәндәсен Хәрәм мәчетеннән әйләнә тирәсен бәрәкәтле иттегебез әл-Әкъса мәчетенә күчергән Ул кемсәгә сокланулы мактау: чынлыкта ул һәрнәрсәне ишетеп күрүчедер» (Коръән, 17:1). Муса әфәнденең әлеге айәттә килгән (هُوَ السَّمِيعُ البَصِيرُ), ягъни «ул һәрнәрсәне ишетеп күрүчедер», дигән гыйбарәне Мөхәммәд пәйгамбәргә караган сүзләр буларак аңлавы алга таба күренәчәк (асыл нөсхә сәхифәләре тәртибендә 94 нче биттә карагыз).

Әгәр бу айәт кәримәне «роэйә», ягъни төш буларак аңлату ярый торган нәрсә булса иде, бу очракта айәт кәримә бер шаяру булыр иде, саташу булыр иде, илаһилек мәртәбәсенә һичнинди сурәттә килешми торган бер уен булыр иде, дәгъват вазифаларына һәрьяклап каршы килгән, файдасы булмаган бер фетнә булыр иде. يجيى و ذهب جاء زيد وذهب, يعنى: راى فى المنام كأنه[1] кеби бер сәчмә[2] булыр иде.

Бер мизгел эчендә Хәрәмнән Мәсҗид Әкъсага барып кайту мәгънәсендә исраъ вакыйгасы җисманидер, дидек. Башка берәү тарафыннан күзәтелмәгән, күрелмәгән булуы аркасында исраъ вакыйгасы могъҗиза була алмый, ягъни нәбилекнең ачыктан-ачык борһаны да түгел, дидек. Болай булса, ул вакыт безнең исебезгә бер сорау килеп төшә:

Кызык, алайса, исраъ вакыйгасының әһәмияте нидә була соң? Аллаһның илаһи хикмәтенә туры килми торган бер файда исраъ вакыйгасында бармы?

Әлбәттә, бар. Нәбиләрнең кулларында чынбарлыкка аша алган могъҗизаларның файдалары бары тик нәбилек борһаны булу кысалары белән чикләнмәгән булса кирәк.

Минем карашымча, исраъ вакыйгасында табыла алган бер файда ошбудыр: киләчәктә гыйлемнең-фәннәрнең, мәгариф вә сәнаигъның ирешә алачак дәрәҗәләрен кешенең акылына һәм күзләренә мисалын китереп күрсәтү, мәдәниятнең максатларына кешеләрнең фикерләрен юнәлдерү була ала. Ягъни, нөбүввәт тәгълиматы белән башланган мәдәният бер мизгелдә гаять зур araларны үтә алу дәрәҗәләренә кадәр тәрәккый итәчәк, димәк була.

Безнең бу «сәййарә»без, ниһаяте юк[3] галәме вөҗүднең газаматына[4] нисбәтән, гаять кечкенә бер зәррә[5] кебек кенә

---

[1] тәрҗемәсе: «Зәед килде дә, китте, ягъни ул төшендә Зәеднең килеп киткәнен күрде».

[2] сәчмә – юк-бар сүз; юк сүз.

[3] ниһаяте юк – ахыры, чиге булмаган.

[4] газамат – олуглык, бөеклек.

[5] зәррә – кыйпылчык, бөртек, кисәкчә; атом; бөртек (мәс.: тузан бертеге; он бөртеге).

булса да, бу кечкенә «зәррә»гә дә хикмәт илаһия гаять зур табигый куәтләр бүләк иткән. Кеше үз иҗтиһады белән ул куәтләрне ачып, үзенә хезмәт иттерә алса, ул чакта кеше бер мизгел дигәндә мең километр араны җиңеллек белән үтә алу кодрәтенә ия булыр. Бәлки бер мизгелдә озын араларны үтү вакыйгалары ул вакытта гади бер нәрсә кебек булып калыр да, рухани куәтләрнең ярдәме белән кеше кулыннан тагын да гаҗәеп хәлләр килер.

Шуңа күрә, мигърадж кичәсендә Нәби мөхтәрәм Кәгъбәдән Мәсҗид Әкъсага күчеп, соңыннан күкләргә ашкан булса кирәк. Нәби мөхтәрәмнең җир йөзендә бер урыннан икенче урынга күчүе матди куәт тәэсире белән булып, күкләргә ашуы рухның куәте белән булган булса кирәк. Юкса, күкләргә туры-дан-туры Кәгъбәдән ашар иде. Минем бу карашымны Коръән кәримдә «эн-Нәмел» сүрәсендә хикәя кыйлынган «Гареш-е Билькыйс»[1] кыйссасы да раслый ала.

قَالَ يَا أَيُّهَا المَلأُ أَيُّكُمْ يَأْتِينِي بِعَرْشِهَا قَبْلَ أَن يَأْتُونِي مُسْلِمِينَ قَالَ عِفْرِيتٌ مِّنَ الْجِنِّ
أَنَا آتِيكَ بِهِ قَبْلَ أَن تَقُومَ مِن مَّقَامِكَ وَإِنِّي عَلَيْهِ لَقَوِيٌّ أَمِينٌ[2]

Ягъни, Сөләйман пәйгамбәр үзенең аксөякләренә: «Гареш-е Билькыйсны миңа кем китерә ала?» – диде. Күзгә күренмәс гыйфритләрнең берсе: «Урыныңнан торып киткәнеңә кадәр (ягъни өч-дүрт сәгать дәвамында) сиңа ул гарешне китерә алам»,– диде.

قَالَ الَّذِي عِندَهُ عِلْمٌ مِّنَ الْكِتَابِ أَنَا آتِيكَ بِهِ قَبْلَ أَن يَرْتَدَّ إِلَيْكَ طَرْفُكَ فَلَمَّا رَآهُ
مُسْتَقِرًّا عِندَهُ قَالَ هَذَا مِن فَضْلِ رَبِّي[3]

---

[1] «Гареш-е Билькыйс» – Билькыйс ханбикәнең тәхете.

[2] «(Сөләйман) әйтте ки: «Йә, аксөякләр! Аларның минем каршыма мөселманнар буларак килеп җиткәннәренә кадәр миңа аның (Билькыйсның) тәхетен кайсыгыз китереп бирә ала? – диде. Җеннәрдән булган бер гыйфрит әйтте: «Мин аны сиңа урыныңнан купканчы китереп бирәчәкмен, чынлап әйтәмен ки, мин моны башкарырлык кадәр куәтлемен һәм ышанычлымын!»,– диде». (Коръән, 27:38–39).

[3] «Китаптан гыйлеме булган берәү: «Мин аны сиңа күзең ачып йомганчы китереп бирәчәкмен!» – диде. Аның (тәхетнең) үз янында пәйда булганын күргән (Сөләйман): «Раббымның фазыйләте белән генә була торган хәл бу!» – диде» (Коръән, 27:40).

Китаптан (табигать китабы, яки галәме вөҗүд китабы булса кирәк) хәбәре булган бер галим: «Мин ул гарешне сиңа бер лөмхә дигәндә (ягъни, күз ачып күз йомганчы) китерә алам»,– диде. Сөләйман пәйгамбәр күзенең уңында ул гарешне күргәннән соң, диде ки: «Мондый бер вакыйга табигать куәте белән була алмый, бәлки бары тик Аллаһның игелеге белән, рухани куәт белән була ала».

Патшабикә Билькыйс ханымның гареше, Коръән кәримнең хәбәренә күрә, Сәба шәһәрендә иде. Сәба шәһәре белән Бәйтел-Мәкъдис[1] арасы – Кәгъбә белән Бәйтел-Мәкъдис арасының, якынча, ике кадәредер.

Гыйфрит үзенең табигый куәте белән Билькыйсның гарешен шулкадәр ераклыктан өч-дүрт сәгать эчендә китерә алса, الَّذِي عِندَهُ عِلْمٌ مِّنَ الْكِتَابِ[2] сыйфаты белән сыйфатланган галим ул гарешне күз ачып йомганчы китереп биргән икән, бу вакыйга хәтта исраъ вакыйгасыннан да, әлбәттә, зуррак була.

Коръән кәримдә бу кадәр ачык сурәттә бәян кыйлынган Билькыйс гареше турындагы кыйсса да роэйә, ягъни төш кенә булып чыгамы?

Әгәр бу кыйсса да роэйә булса, ул чакта Коръән кәримнең бөтен кыйссалары бер саташу гына булмасмы?

Әгәр дә тәхетнең Йәмәннән Бәйтел-Мәкъдискә кадәр бер мизгелдә хәрәкәт итүе роэйә булмыйча, бәлки хакыйкать булса, Нәби кәримнең Кәгъбәдән Бәйтел-Мәкъдискә кадәр бер сәниядә[3] күчүе, әлбәттә, хакыйкать була, роэйә булмас.

Гаҗәп, Коръән кәримдә Билькыйс патшабикәнең тәхете турындагы кыйсса ни өчен зикер кыйлынган?

Сөләйман пәйгамбәрнең шәүкәтеннән, куәтеннән, газаматыннан, дәүләтеннән безне хәйран калдыру өчен генәме?

Яки әһле кәлам даирәсендәге җаһилләрнең тәэвилдә мәһарәтләрен[4] тәфсир китапларында безгә күрсәтү өченме?

---

[1] Бәйтел-Мәкъдис – Изге Йорт, ягъни Иерусалим шәһәре.

[2] «Китаптан гыйлеме булган берәү» (Коръән, 27:40).

[3] сәния (гарәп.) – секунда.

[4] мәһарәт (гарәп.) – осталык; уңганлык.

Яисә табигать хәзинәләрендә һаман яшерен хәлдә кала биргән иң олы матди куәтләргә, һәм дә матди куәтләрдән дә өстен булган рухани куәтләргә инсанның фикерен юнәлдерү өченме, күзгә күренмәс гыйфритнең куәте белән, айәттә искә алынган الَّذِي عِندَهُ عِلْمٌ مِّنَ الْكِتَابِ[1] берәүнең куәтен безгә бәян итәр өчен искә алынганмы?

Гаять матур бу кыйссадан кешенең акылын хәрәкәткә китерүгә караган иң зур үзенчәлек, әлбәттә, будыр.

Коръән кәримнең бу кыйссасы гыйбрәт өчен зикер кыйлынган тарихи хикәя түгел. Бәлки инсанның фикерен галәме вөҗүдтә бар булган иң олы куәтләргә юнәлдерү өчен зикер кыйлынган бер тарихи хакыйкатьтер.

Гареш-е Билькыйс[2] Йәмәннән Бәйтел-Мәкъдискә, берсе өч сәгатьтә, икенчесе бер мизгел эчендә китерә алган ике куәт турында кеше Коръән кәримдә укыса, Коръән кәримнең хәбәренә иман итеп, ул ике куәтне галәме вөҗүдтә эзләсә, ахырда иҗтиһадының бәрәкәте белән кешелек дөньясы шул ике куәтне табып ачса, менә шунда Коръән кәримнең кыйссаларына салынган үзенчәлек шундый булыр. Әлегә кадәр гафил булганбыз икән, гаеп, әлбәттә, бездәдер.

Коръән кәримдә хәбәр ителгән бу ике куәтне инкяр итү гыйлем түгел, наданлыктыр, җаһилллектер. Аларны голүм исеме белән инкяр итү голүмнең шәрәф вә мәртәбәсенә карата кыйлынган җинаять булыр, голүмнең тәрәккыятенә каршы киртә кору, юл буу кебек бер мәгъруриять булыр.

***

Коръән кәримдә мәзкүр[3] «исраъ» вакыйгасы да, катгый Сөннәттә расланган мигъраҗ вакыйгасы да галәме вөҗүдтә була торган матди һәм рухани куәтләргә кешенең фикерен юнәлдерү юлы белән искә алынган булса кирәк.

«Исраъ» хәдисәсе[4], Кәгъбәдән Мәсҗид Әкъсага җир йөзе буйлап хәрәкәт итү мәгънәсе белән, әлбәттә, табигый куәт

[1] «Китаптан гыйлеме булган берәү» (Коръән, 27:40).

[2] Гареш-е Билькыйс – Билькыйснең тәхете.

[3] мәзкүр – искә алынган.

[4] хәдисә – вакыйга; булган хәл.

арадашлыгы белән булган булса кирәк. «Исраъ» хәдисендә мәзкүр «борак» сүзе дә электрик мәгънәсендә булган «бәрык» сүзенең арттыру шәкеле кебек булса кирәк.

Гарәп телендә *фөгаль* (فعال) кебек сүз ясалышы калыбы, күбесенчә, арттыруны, чикне узуны белдерә торган корылма булып килә; 1) *гаҗибә* (عجب)[1] тамырыннан ясалган *гоҗаб* (عجاب)[2] кебек, 2) *гариб* (غريب)[3], *гарабәт* (غرابت)[4] кебек сүзләрдән ясалган *гораб* (غراب)[5] кебек.

جرى بفراق جيرتنا غراب: فعال من مقالتنا غريب[6] (әл-Ләзүмийәт).

Бүген безгә мәгълүм булган табигый куәтләрнең иң олысы – яшен куәтедер. «Борак» сүзе «бәрык»ның, ягъни «яшен»нең арттыру, гипербола шәкеле булса, димәк, табигать хәзинәләрендә электриктан тагын да куәтле булган бер табигый куәт бар. Электрик бер сәниядә ниһаяте юк араларны уза алса, бурак бер сәниядә ниһаяте юк араларны уздырта ала.– «Боракка атланмак» – иң олы табигый куәт ярдәме белән хәрәкәт итмәк мәгънәсендә була ала. Исраъ төнендә Сәййидел-вөҗүд хәзрәтләренең хезмәте белән Җибрил Әмин кебек иң олуг Рух әл-кодус (рухани куәт) мәшгуль булган икән, әлбәттә, Борак рухани куәттән гыйбарәт була алмый, ул бер табигый куәт булган димәк.

Исраъ хәдисәсе, әлбәттә, җисманидер[7], дигән идек. Бу вакыйга матди табигый куәт бәрәкәте белән, хезмәте белән булган дидек, ләкин рухани куәт ярдәме белән дә була ала. Фәкать, һәрхәлдә, ул җисманидер, уяу хәлдә булган нәрсәдер.

[1] гаҗибә – сокланырга; хәйран калырга, гаҗәпләнергә.

[2] гоҗаб – искитәрлек, искитмәле; могҗизави; гаҗәп.

[3] гариб – ят, таныш булмаган; гаҗәп, гадәттән тыш; сәер.

[4] гарабәт – сәерлек; гадәттән тыш булучанлык;

[5] гораб – әлеге сүзнең сүзлектәге мәгънәләре: карга, каргасыман кошлар; оч, кылычның очы. Әмма аңлашылганча, Муса әфәнде бу сүзнең нигезендә яткан тамыр фигыльнең мәгънәләрен күздә тоткан: билгесез булырга; ят булырга; сәер булырга.

[6] тәрҗемәсе: Ниндидер сәер (фөгаль) һәм куркыныч нәрсә арабызны өзде.

[7] җисмани – җисем хәлендә; гәүдә булган хәлдә; гәүдә белән бергә.

Әмма мигъраҗ вакыйгасы исә, әлбәттә, роэйә, ягъни төш, төштә күренгән вакыйга түгел иде, бәлки уяу хәлдә иде, хакыйкый, нәбилекнең гаять олы бер хосусыяте, үзенчәлеге иде.

Ләкин җисмани идеме? Рухани идеме? Һәрбере ихтималдыр.

Әгәр дә рухани мигъраҗ игелеклерәк булмаса иде, мин «мигъраҗ да, әлбәттә, җисманидер»,– дияр идем. Чөнки Коръән кәримдә катгый сурәттә мигъраҗның җисмани булуы раслана.

Безнең инануыбызга күрә, рух, куе матдәдән һәрникадәр ару булса да, нурани, ягъни нурдан гыйбарәт булган җисемдер. Фәрештәләр дә нурани җисемдер. Бу мәсьәләдә фәлсәфә карашына безнең игътикадыбыз, дөрес, каршы килә. Ләкин безнең кулыбызда, бу игътикадыбызны исбат итеп, фәлсәфә карашын юкка чыгара алыр кадәр куәтле дәлилләр, борһаннар бар. Шуңа күрә, фәрештә – җисемдер, рух – җисемдер, дип әйтә алабыз.

Коръән кәримдә «әл-Мәгариҗ» сүрәсендә تَعْرُجُ الْمَلَائِكَةُ وَالرُّوحُ إِلَيْهِ فِي يَوْمٍ كَانَ مِقْدَارُهُ خَمْسِينَ أَلْفَ سَنَةٍ[1], дигән айәт кәримә фәрештә һәм Рух хакында горуҗны[2], ягъни күккә ашуны исбат иткән. Димәк, рухани җисемнәр горуҗ итә алалар, күккә аша алалар.

Коръән кәримдә «әл-Хиҗер» сүрәсендә, мөҗримнәрнең[3] кирелекләрен бәян итү буларак иңгән:

وَلَوْ فَتَحْنَا عَلَيْهِم بَابًا مِّنَ السَّمَاء فَظَلُّواْ فِيهِ يَعْرُجُونَ لَقَالُواْ إِنَّمَا سُكِّرَتْ أَبْصَارُنَا بَلْ نَحْنُ قَوْمٌ مَّسْحُورُونَ[4]

дигән айәт кәримә кешеләр хакында да горуҗнең мөмкин булуын белдерә. Чөнки шарт җөмләдә һәрбер тарафның мөмкин

[1] «Фәрештәләр һәм Рух озаклыгы илле мең ел булган бер көндә шунда ашалар» (Коръән, 70:4).

[2] горуҗ – күккә ашу, мигъраҗ.

[3] мөҗрим – җинаятьче, ягъни Аллаһны танымавы сәбәпле рухына карата җинаять кыйлучы.

[4] «Әгәр Без алар алдында күк капуларының берсен ачсак, һәм алар [шул капка аша күккә] үтеп керсәләр, һичшиксез: «Безнең күрү кабилиятебез исертелгән булган икән! Чынлыкта без сихерләнгән кешеләр икәнбез!»,– дип әйтерләр иде» (Коръән, 15:14–15).

булуы мантыйкның горефенә күрә тиешле булмаса да, Коръән кәрим горефендә мөмкин булуы, рөхсәт ителгән булуы, әлбәттә, тиештер.

Фараз итик, пәйгамбәрнең мигъраҗы җисмани булган. Бу тәкъдирдә ул мигъраҗ табигый куәт ярдәме белән була ала. Рухани илаһи куәт бәрәкәте белән дә була ала. Ләкин хәдис гыйбарәсенең тышкы кыяфәтенә күрә, табигый куәт ярдәме белән түгел, бәлки илаһи куәт бәрәкәте белән булган.

«Мөснәд Әхмәд»тә[1] сәхаби Хөзәйфәдән[2] риваять кыйлынмыш: اتيت بالبراق و هو ابيض طويل يضع حافره عند منتهى طرفه. فلم نزايل ظهره انا و جبريل حتى اتيت بيت المقدس[3]

Бу хәдистә Боракка атлануның максаты бәян ителгән. Димәк, күкләргә ашу Боракка атланган хәлдә булмаган.

Күккә җисмани хәлдә ашу табигый куәт тәэсире белән булса да, илаһи куәт бәрәкәте белән булса да, һәрхәлдә, җазибият канунына да, тиз хәрәкәттән килеп чыккан эсселек куәте белән ихтиракъ канунына[4] да каршы килми.

Бер мөкаддимә рәвешендә, (68–69) сәхифәләрдә китерелгән 4 нче, 5 нче һәм 6 нчы фикерләргә, һәм дә могъҗизаның мөмкин булуы турында сүз йөрткәндә, 2 нче номер астында әйтелгән сүзләргә мөрәҗәгать итсәк, каршылык юклыгы, әлбәттә, ачыктан-ачык күренәчәк. Чөнки тагын да зуррак куәт булганда, зәгыйфь куәт юкка чыкмый, ул гамәлдән чыгарыла; тагын да үтемле тәэсирле канун булганда, гади канун гамәлдән чыгарылып тора.

Җазибият кануныннан өстен булган бер табигый куәт яки рухани куәт бер җисемне гаддәттән тыш тизлек белән югары чыгара ала. Сулыш алу канунынннан тагын да өстен булган бер илаһи канун кешенең исәнлеген андый чакта саклый ала, хәрәкәтне эсселек

---

[1] «Мөснәд Әхмәд» – милади 780–855 нче елларда гомер иткән һәм хәнбәли сөнни фикъһы мәзһәбенә нигез салучы имам Әхмәд ибне Хәнбәл әш-Шәйбани хәзрәтләренең каләме белән язылган һәм үз эченә 40000гә якын хәдис алган җыентык.

[2] Хөзәйфә – «Шәхесләр турында белешмә»не карагыз.

[3] Тәрҗемәсе: Минем яныма Боракны китерделәр. Аның төсе ак иде, гәүдәсе озын, тоякларының очлары гына җиргә тиеп тора иде. Җәбраил белән минем аңа атланубыз булды, шул ук мизгелдә Бәйте-Мәкъдискә барып җиттек.

[4] ихтиракъ кануны – үтеп керү; матдә аша үтәли узу кагыйдәсе.

дәрәҗәсе артуыннан дә коткара ала.

Кыскасы, күккә ашу җисмани була алса, безгә мәгълүм булган табигый куәтләр, табигый кануннар юкка чыкмыйлар, бәлки тагын да куәтлерәк булган куәтләр хозурында җиңеләләр генә. Шәригать теле белән әйтсәк, Аллаһның илаһи кодрәте хозурында إِنِ الْحُكْمُ إِلَّا لِلَّهِ[1] дигән зикер белән сәҗдә итеп, буйсына, аның бөтен тәэсире илаһилыкның كُن فَيَكُونُ[2] дигән канунына тапшырыла да, илаһи куәт хозурында әдәплелек күрсәтү юлы белән кулларын баглый, гамәлсез, хәрәкәтсез кала.

***

Пәйгамбәрнең мигъраҗы җисмани булмаган, бәлки рухани булгандыр, дип фараз итик. Бу ихтимал нәби кәрим расүл әмин галәйһис-саләтү вәс-сәламү хәзрәтләренең гаять бөек мәртәбәләренә тагын да туры килә. Чөнки мигъраҗ рухани булса да, ул төштә, йокыда түгел иде, бәлки уяу хәлдә иде. Кешенең җисеменә нисбәтән чагыштырылмаслык дәрәҗәдә куәтлерәк рухы хакында чынбарлыкта булган хакыйкый һәм гаять бөек хәлләрдән гыйбарәт иде мигъраҗ. Рух хакында чынбарлыкта булган ул хәлләр – бер җисемнең күкләргә ашуы кебек гади хәлләрдән һәрьяклап олырак иде, әһәмиятләре дә, әлбәттә, олырак иде, бөтен кешелек дөньясына аталган рисаләтнең дәрәҗәсенә тагын да туры килә торган бер фазыйләт[3] иде. Чөнки рухани горуҗ – инсаният өчен мөмкин була алган камиллек дәрәҗәләрен, мәртәбәләрен кисеп ату мәгънәсендәдер.

Югарыда яздык: кеше туганда, игелекләрдән мәхрүм булып, кимчелекләрдән пакь була, кешедә бары тик кабилият, бары тик яраклылык була. Кешенең кабилиятенә, инсанның яраклылыгына чик юк. Инсаннар теге яки бу эшкә яраклылык ягыннан төрле булсалар да, һәрбер кеше иге-чиге булмаган теге яки бу төр камиллекләргә ияләр.

Теге яки бу ике камиллек арасында ара гаять озындыр. Табигать хәзинәсендә тәрбия кыйлына торган кеше ул араны

[1] «Хөкем бары тик Аллаһның карамагындадыр» (Коръән, 6:57).

[2] «Бул! Һәм ул бар була» (Коръән, 3:59).

[3] фазыйләт – яхшылык, игелек; өстенлек.

бик акрын уза. Табигый куәте белән мәшрикътән[1] мәгърибкә[2] хәрәкәт иткән инсан ике араны, мәсәлән, бер ел эчендә уза ала. Әмма ике кямиллек арасында булган араны инсаният ике-өч ел эчендә уза алмый, моның өчен аңа бәлки биш-ун гасыр, хәтта берничә дәвер ляземдер. Шуңа күрә, ниһаяте булмаган араны бер мизгелдә узу чагыштырмача җиңелдер. Әмма ниһаяте юк кямиллек дәрәҗәләрен вә мәртәбәләрен бер мизгелдә, яки бер сәгать эчендә узу табигать кануннарына каршы килә, табигать куәтләренең тәкатьләреннән[3], әлбәттә, артып китә, [табигать куәтләре өчен бу] гаять авырдыр. Табигатьтә инсанның акылын дәһшәтләндерә алырлык тизлекнең мисаллары, шаһитлары гаять күп. Ләкин кямиллек дәрәҗәләрен тизлек белән кисеп ату табигатьтә юк: хайванның, үсемлекнең, мәсәлән, үсүе-җитешүе акрын гына үз тәртибе белән бара. Җисемнәрнең кямил шәкеле заман ярдәме белән хасыйль була. Кешенең кәйфият нәфсаниясе[4], акылының кямиллеккә ирешүе, бәдәненең өлгергән шәкелгә җитешүе озын заманның җимеше була.

Нәби кәримнең мигъраҗы рухани булса, ягъни бөтен инсаният өчен мәңгелекнең ахырларында гына мөмкин була ала торган кямиллекнең бөтен дәрәҗәләрен нәби кәримнең рухы берничә мизгел эчендә узган булса, андый бер мигъраҗ могъҗизаларның могъҗизасы булыр, миллион күкләрнең өстенә чыгудан миллион мәртәбә артык булыр, рисаләтнең, нәбилекнең мәртәбәсен ассызыклаган иң зур кямиллек, иң гүзәл фазыйләт булыр.

Шулай булу, әлбәттә, ляземдер, яки безнең игътикадыбызга иң туры килгәне шулай булудыр. Чөнки инсаният илаһилекнең көзгеседер. Илаһилек үзенең бөтен исемнәре белән инсаният йөзендә күренә. Инсан илаһилек исемнәренең, илаһилек кәмальләренең[5] һәрберен үзендә чагылдыручыдыр:

---

[1] мәшрикъ – кояш чыга торган тараф, көнчыгыш.

[2] мәгъриб – кояш бата торган тараф, көнбатыш.

[3] тәкать – көч; егәр, энергия.

[4] кәйфият нәфсания – психологик сурәт.

[5] кәмаль – җитешкәнлек, тулылык, өлгергәнлек; кямиллек; кимчелексез, тулы, бөтен.

хәят, ирадә[1], гыйлем, кодрәт, ихтыяр, хикмәт, хөкем, кәлам[2], холык, тасвир[3], ибдаг[4], мәрхәмәт, игелеклек, юмартлык, йомшаклык-юашлык, гафу, ачу, каһәр[5], кибрия[6], гаделлек, әмер[7], гыйззәт, җәлал[8], җәмал кебек илаһилек исемнәренең, илаһилек кәмальләренең һәрберенә кеше, әлбәттә, үзендә чагылдыручыдыр.

Кешедә булган һәрбер кәмаль илаһилеккә хас булган кәмальләренең чагылышыдыр, күләгәседер. Ләкин кабилиятнең төрле булуына күрә, һәрбер кеше кәмальнең һәрберен бер дәрәҗәдә чагылдыручы була алмый. Бөтен инсаният илаһилекнең бөтен кәмальләрен чагылдыручы булу шәрәфенә дә кыска заманда ирешә алмый. Илаһилек кәмальләренә, илаһилек исемнәренә тулысынча ирешкән бер кешенең булуы бөтен инсаниятнең шәрәфе хакына, әлбәттә, кирәк иде, тиеш иде. Арада андый бер кешенең булмавы, инсаният шәрәфенә, бераз булса, да җитешсезлек була алырлык хәлдер.

Инде рухани мигъраҗ вакыйгасы белән ул кимчелек юкка чыгарылган булса кирәк. Могъҗизаларның могъҗизасы буларак, инсани кямиллекнең бөтен дәрәҗәләрен бер төн эчендә үткән инсан бөтен кешелек дөньясын бизәгән булса кирәк.

Рухани горуҗ шуннан гыйбарәт. Ул төш-роэйә түгел, бәлки хакыйкать, чынбарлык, шөбһәсез сурәттә уяу хәлдә булган нәрсә. Гадәттән тыш булуы ягыннан рухани горуҗ җисмани горуҗдан күпкә өстенрәк.

---

[1] ирадә – аңлы рәвештә нәрсәне дә булса теләү, эстәү, нәрсәгә булса да омтылу; ихтыяр.

[2] кәлам – кешенең сүз иясе булуы; сөйләшә белүе; сөйләм ярдәмендә аралаша алуы күздә тотыла.

[3] тасвир – кешенең күргәнен, ишеткәнен, сизгәнен, тойганын һәм башка нәрсәләрне сурәтли алуы, тасвирлый алуы күздә тотыла.

[4] ибдаг – уйлап чыгару; иҗат.

[5] каһәр – көчләү, җәберләү.

[6] кибрия – зур дәрәҗәлелек; горурлык; олылык; олуглык.

[7] әмер – боерык; әмер итә алу, әмер иясе булу; идарә итә алу.

[8] җәлал – бөеклек, олылык.

***

Инсан, рухани мигъраҗ бәрәкәте белән, илаһилек кәмальләренең һәрберен дә, һәммәсен дә күрсәтүчедер дидек. Ләкин инсан һаман инсан булып кала. Кеше кямиллек нурыннан, илаһилек нурларыннан тулысынча файдалана, кешедә кямиллек нурлары, ай нуры кебек, һәрвакыт балкып тора. Илаһилек кәмальләренә, илаһилек исемнәренә бары тик бер «зат-ы өлүһият»[1] бары тик бер җиһәт белән мәбдәъ[2] була. Әмма кешенең заты кямиллекнең һичберсенә мәбдәъ булмас, кешенең һәрбер кямиллеге чагылдыру юлы белән хасыйль була, моның өстенә кешедә бер җиһәт белән һичкайчан да ике кәмаль хасыйль була алмый. Һәр кәмальнең үзенә хас җиһәте, үзенә хас нигезе бар: күрмәк – күз белән, ишетмәк – колак белән, аңламак – баш мие белән, хисләр – йөрәк белән, көч – газаләт[3] белән. Һәм башкалары да шулай.

Гаять мөһим булган бу үзенчәлек турында фикер йөртсәк, илаһилек кәмальләренең һәммәсен үзендә чагылдыручы булган инсан белән зат-ы өлүһиятне бик ачык сурәттә аера алабыз; өлүһият белән инсаният араларын аера торган ахыры булмаган араларны анык бер сурәт белән, бәлки, сурәтли дә алабыз.

Бу мәсьәләне ислам фәлсәфәсе, ягъни тәсаувыф, тәфсилләп аңлаткан булса да, биредә урынына күрә, бу кадәре дә җитеп тора.

«Исраъ» вакыйгасы җисмани булган, уяу хәлдә булган дидек. Мигъраҗ вакыйгасы да йә җисмани, йә рухани булып, [пәйгамбәрнең] уяу чагында булган дидек. Фикерләү мәшәкатьләре белән баш миләрен ардырудан сакланган кайбер назлылар, «Бәни Исраъил» сүрәсендәге وَمَا جَعَلْنَا الرُّؤيَا الَّتِي أَرَيْنَاكَ إِلَّا فِتْنَةً لِّلنَّاسِ[4], дигән айәт кәримә белән дәлилләп, «исраъ вакыйгасы да, мигъраҗ вакыйгасы да роэйәдә иде»,– дияләр.

[1] зат-ы өлүһият – илаһи зат; илаһилекнең асылы.

[2] мәбдәъ (гарәп.) – башлангыч, принцип.

[3] газаләт (гарәп.) – әгъзаларны хәрәкәткә китерә торган итләр, сум ит; мускуллар.

[4] «Безнең сиңа күрсәткән роэйәне кешеләр өчен фетнәдән башка һични итмәгән идек» (Коръән, 17:60).

Назлыларның фикерләренә, әйдәгез, мин дә вакытлыча гына кушылыйм да: «Бу айәт кәримә «исраъ» вакыйгасына, я мигъраҗ вакыйгасына ишарәдер»,– диим.

Ләкин бераз фикер йөртик: биредә الَّتِي أَرَيْنَاكَ[1] кебек гаять олы, гаять газаматлы сүзтезмә, гаҗәп, ни өчен искә алынган икән? Нигә التى رأيتها[2] кебек сүзтезмә белән генә чикләнелмәгән?

Дөрес, Коръән кәримдә رويا *роэйә* сүзе йоклаган чакта була торган төш мәгънәсендә кулланылган. Ләкин ул йә мотлак, ягъни бәйсез, үз башына бер нәрсә буларак зикер кыйлынган, йә, булмаса, тәэвил кебек, тәгъбир кебек, فى المنام[3] кебек, раслау кебек чикләү зикер ителеп, хакыйкатьне бәян кыйлган.

1) قَالَ أَحَدُهُمَا إِنِّي أَرَانِي أَعْصِرُ خَمْرًا وَقَالَ الآخَرُ إِنِّي أَرَانِي أَحْمِلُ فَوْقَ رَأْسِي خُبْزًا تَأْكُلُ الطَّيْرُ مِنْهُ نَبِّئْنَا بِتَأْوِيلِهِ[4]

2) يَا أَيُّهَا الْمَلأُ أَفْتُونِي فِي رُؤْيَايَ إِن كُنتُمْ لِلرُّؤْيَا تَعْبُرُونَ[5]

3) إِنِّي أَرَى فِي الْمَنَامِ أَنِّي أَذْبَحُكَ[6]

4) لَقَدْ صَدَقَ اللَّهُ رَسُولَهُ الرُّؤْيَا بِالْحَقِّ[7]

5) قَالَ يَا بُنَيَّ لاَ تَقْصُصْ رُؤْيَاكَ عَلَى إِخْوَتِكَ[5]

Әлеге айәт кәримәләрдә رويا *роэйә* сүзе, әлбәттә, «төш» мәгънәсендәдер. Ләкин الَّتِي أَرَيْنَاكَ[8] кебек гаять газаматлы сүзтезмә белән чикләнелгән الرُّؤيَا[9] *әр-роэйә* безгә мәгълүм булган гади бер төш була аламы?

[1] «Безнең сиңа күрсәткән. « (Коръән, 17:60).

[2] әлеге ясалма сүзтезмәнең тәрҗемәсе: «Син (үзең) күргән…».

[3] тәрҗемәсе: «йоклаганда»; «төштә».

[4] «Ул икәүнең берсе әйтте: «Чындыр ки, үземнең хәмер басканымны күрдем!», ә икенчесе: «Чындыр ки, мин баш өстемдә икмәк тотып барганымны, шул икмәкне кошлар ашаганын күрдем! Безгә боларның юралышын хәбәр итче!» – диде». (Коръән, 12:36).

[5] «Әй, аксөякләр! Әгәр төш юрый беләсез икән, миңа төшемне юрап бирегез!» (Коръән 12:43).

[6] «Чындыр ки, төшемдә сине чалганымны күрдем!» (Коръән, 37:102).

[7] «Чындыр ки, Аллаһ үзенең расүлен (шул) хак төш белән раслады инде» (Коръән, 48:27).

[8] «Безнең сиңа күрсәткән…» (Коръән, 17:60).

[9] әр-роэйә – биредә сүзнең (ال) әл – кисәкчәсе белән белдерелгән билгеле хәлдә булуын истә тотарга кирәк.

Әгәр дә гади бер төш булса иде, Аллаһның кодрәт илаһиясен Нүн-е газамат[1] белән ассызыклауда, кызык, нинди дә булса бер файда, нинди дә булса бәлягать булыр идеме?

Дөрес, Коръән кәримдә «әл-Әнфаль» сүрәсендәге إِذْ يُرِيكَهُمُ اللّٰه فِي مَنَامِكَ قَلِيلاً[2], дигән айәт кәримәдә Аллаһның үзенә бәйләнгән, ягъни үзеннән күрсәтелгән *роэйә* бар, ләкин فِي مَنَامِكَ[3] дигән чикләү белән хакыйкате бәян кыйлынган.

Нун-е газамат белән Аллаһның илаһи кодрәтенә бәйләнгән «*әр-роэйә*» һичничек безгә мәгълүм булган гади төш кебек була алмый, юкса, шулкадәр газаматлы сүзтезмә әһәмиятсез булып калыр иде; илаһи сүз могъҗизави бәлягать дәрәҗәләрен югалтыр иде.

Дөрест, роэйә үзенең халыкта таралган мәгънәсе белән, күбесенчә, төшне белдерә. Ләкин Коръән горефенә күрә бу сүз төш мәгънәсен белдерми булса кирәк. Сүз ясалышы кагыйдәләре дә моны дәлилли ала. *Ръй* (راى)[4] тамырыннан ясалган исем калыплары да, фигыль калыплары да күз белән күрүне белдерә ала. Аның мәшһүр һәм киң кулланышлы булу сүзнең нинди дә булса бер тар мәгънәгә ия булуын дәлилләүгә комачау итә алмый. *Роэйә* رويا сүзе сүз ясалышы кагыйдәсе белән *роэйәт*[5] رويت мәгънәсендә була ала. Моның шулай булуын раслый торган берничә катгый дәлил бар:

1) Әгәр дә الرُّؤيَا الَّتِي أَرَيْنَاكَ[6] дигән сүзтезмәдә роэйә сүзе төш мәгънәсендә булса иде, мигъраҗ турысында «ән-Нәҗем» сүрәсенең башында иңгән وَالنَّجْمِ إِذَا هَوَى مَا ضَلَّ صَاحِبُكُمْ وَمَا غَوَى

[1] Нүн-е газамат (олуглык Нүне) – Коръәндә Аллаһы тәгаләне белдергәндә кулланылган نا (Без) алмашлыгындагы нүн хәрефе күздә тотыла.

[2] «Менә Аллаһ төшеңдә сиңа аларны аз итеп күрсәтте» (Коръән, 8:43).

[3] «…төшеңдә…» (Коръән, 8:43).

[4] ръй (راى) – ра-һәмзә-йай хәрефләреннән гыйбарәт булган һәм икенче хәрефе һәмзә, өченчесе – зәгыйфь хәреф булган икеләтә дөрес булмаган тамыр. Әлеге тамырдан «күрергә» мәгънәсенә ия булган раъә (راى) фигыле ясала.

[5] роэйәт – күрү; күңел күзе белән күрү; яңа айны күрү; төш күрү.

[6] «Безнең сиңа күрсәткән роэйәне…» (Коръән, 17:60).

وَمَا يَنطِقُ عَنِ الْهَوَى إِنْ هُوَ إِلَّا وَحْيٌ يُوحَى عَلَّمَهُ شَدِيدُ الْقُوَى ذُو مِرَّةٍ فَاسْتَوَى وَهُوَ بِالْأُفُقِ الْأَعْلَى ثُمَّ دَنَا فَتَدَلَّى فَكَانَ قَابَ قَوْسَيْنِ أَوْ أَدْنَى فَأَوْحَى إِلَى عَبْدِهِ مَا أَوْحَى مَا كَذَبَ الْفُؤَادُ مَا رَأَى أَفَتُمَارُونَهُ عَلَى مَا يَرَى وَلَقَدْ رَآهُ نَزْلَةً أُخْرَى عِندَ سِدْرَةِ الْمُنْتَهَى عِندَهَا جَنَّةُ الْمَأْوَى إِذْ يَغْشَى السِّدْرَةَ مَا يَغْشَى مَا زَاغَ الْبَصَرُ وَمَا طَغَى لَقَدْ رَأَى مِنْ آيَاتِ رَبِّهِ الْكُبْرَى[1], кебек бик зур айәт кәримәләр мәгънәсез җөмләләрдән, чынлыгы булмаган, асылы булмаган хыяллардан гыйбарәт булып калыр иде.

2) Әгәр дә الرُّؤيَا الَّتِي أَرَيْنَاكَ[2], дигән гыйбарә төш мәгънәсендә булса иде, وَمَا جَعَلْنَا[3], дигән сүзне وَإِذْ قُلْنَا لَكَ إِنَّ رَبَّكَ أَحَاطَ بِالنَّاسِ[4], дигән җөмләдән соң искә алу файдасыз, урынсыз булыр иде. Һәм әлеге айәт кәримәне وَمَا مَنَعَنَا أَن نُّرْسِلَ بِالآيَاتِ إِلاَّ أَن كَذَّبَ بِهَا الأَوَّلُونَ وَآتَيْنَا ثَمُودَ النَّاقَةَ مُبْصِرَةً فَظَلَمُواْ بِهَا وَمَا نُرْسِلُ بِالآيَاتِ إِلاَّ تَخْوِيفًا[5],

[1] «Баеп күздән югалган Йолдыз белән ант итәм ки: сезнең юлдашыгыз адашмады да, юлдан да язмады. Ул үзе теләгән нәрсәләр сөйләми. Ул (аның сөйләгәне) аңа иңдерелгән вәхидән башка һични түгел. Аны ифрат та көчле һәм үткен акыллы Зат өйрәтте. Менә ул (Зат) торып басты һәм ул иң югары офыкта иде. Аннан соң ул түбәнгә иңде дә ике җәя атышы кадәр, яки аннан да кимрәк итеп якыная төште. Аннан соң ул (Аллаһның) бәндәсенә вәхий кыйлачагын вәхий кыйлды. Күргәннәрен (расүлуллаһның) йөрәге ялган дип санамады. Сез аның белән аның (үз күзләре белән) күргәннәре хакында тартышасыз түгелме? Ул аны башка бер иңүендә үзенә кайтылачак җәннәттә, аның янәшәсендә булган соңгы чиктәге сидрәт янында да күргән иде. Сидрәтне каплаган нәрсә каплаганнан соң, аның (расүлуллаһның) күз карашы читкә тайпылмады һәм чиктән узмады: ул Раббысының иң бөек айәтләреннән иң мөһим бер өлешен күрде» (Коръән, 53:1–18).

[2] «Безнең сиңа күрсәткән роэйәне…» (Коръән, 17:60).

[3] «…һич ни итмәгән идек» (Коръән, 17:60).

[4] «Менә Без сиңа: «Чынлыкта Раббың кешеләрне колачлапбиләп тора»,– дидек» (Коръән, 17:60).

[5] «Безне айәтләр юллаудан әүвәлгеләрнең аларны ялганга чыгарулары гына тотып калды. Без сәмуд кабиләсенә ачыктан-ачык айәт буларак ана дөя китергән идек, ә алар аңа карата золым кыйлдылар. Шуңа күрә без айәтләрне куркыту өчен генә юллыйбыз» (Коран, 17:59). Тәрҗемәченең аңлавына күрә, айәтнең мәгънәсе ошбудыр: «Кешеләрнең айәтләрдән йөз чөерүләре Аллаһны аларга үзенең бар-

дигән айәт кәримә янәшәсендә иңдерү урынлы булмас иде, чөнки Салих кебек пәйгамбәрнең ана дөя кебек могъҗизасы искә алынганнан соң, ислам пәйгамбәре булган Сәййиделәнбия[1] хакында бары тик хыялдан гыйбарәт булган бер төш күрдерү, әлбәттә, кимәлгә туры килми. Бәлки расүлләрнең әфәндесе хакында гаҗәпләрнең дә гаҗәбе булган бер нәрсәнең зикер кыйлынуы урынлыдыр.

3) Безгә мәгълүм булган мәгънәсе белән роэйә һичбер сурәттә фетнә була алмый. Мөшрикләрнең авызлары белән таратылган фетнә Нун-е газамат белән Аллаһның үзенә һичбер вакыт кайтарып калдырыла алмый. Андый вак-төяк фетнәләр Коръәннең горефенә күрә һәрвакыт инсаннарның бары тик үзләренә кайтарып калдырыла. Мәсләлән, إِنَّ الَّذِينَ يُحِبُّونَ أَن تَشِيعَ الْفَاحِشَةُ فِي الَّذِينَ آمَنُوا[2], дигән айәттәге кебек.

Искә алынган وَمَا جَعَلْنَا الرُّؤيَا الَّتِي أَرَيْنَاكَ إِلاَّ فِتْنَةً لِّلنَّاسِ[3], дигән айәт кәримәдә телгә алынган фетнә, әлбәттә, илаһилек куәте белән гамәлгә ашырылган фетнә генә була ала. Әгәр дә мөшрикләрнең авызлары белән таратылган фетнә күздә тотылачак булса, ул чакта хасыр[4] ялган булыр иде. Чөнки, сезнең сүзләр белән әйтсәм: ул төштә вак-төяк фетнәләргә сәбәп булудан башка, зуррак файдалар, биш намазны фарыз итү кебек бөек мәсълихәтләр, әлбәттә, бар иде. Гаять вак фетнәләрне Нүн-е газамат белән үзенә кайтарып та, гаять олы мәсълихәтләр турында дәшми калу илаһилекнең бәля-

---

лыгы турында галәмәтләр юллап торуыннан һичкайчан да туктатмаячак».

[1] Сәййиделәнбийә (гарәп.) – Пәйгамбәрнең әфәндесе, ягъни Мөхәммәд пәйгамбәрﷺ.

[2] «Чынлыкта, йөрәкләре белән иман иткәннәр турында яманат таратырга яратучылар. « (Коръән, 24:19). Айәтнең тулы тәрҗемәсе: «Чынлыкта, йөрәкләре белән иман иткәннәр турында яманат таратырга яратучылар – алар өчен дөньяда да, ахирәттә дә әрнетүче газаптыр. Аллаһ белә, ә сез белмисез».

[3] «Безнең сиңа күрсәткән роэйәне кешеләр өчен фетнәдән башка һич ни итмәгән идек» (Коръән, 17:60).

[4] Биредә хасыр (чикләү; аерып күрсәтү) фетнәнең Аллаһ тарафыннан кылынганын ассызыклаудан гыйбарәт.

гатьле үтемле теленә дә, Коръән кәримнең игъҗазына да һич килешә торган хәл түгел.

Әгәр дә الرُّؤيَا الَّتِي أَرَيْنَاكَ[1], дигән гыйбарәдә искә алынган роэйә төштән гыйбарәт булып, фетнә мөшрикләр тараткан сүзләрдән гыйбарәт булса иде, ул очракта وَالشَّجَرَةَ الْمَلْعُونَةَ[2], дигән сүзне әр-роэйә сүзе белән бер сафка куюда нинди дә булса мөнәсәбәт вә мәгънә калмас иде.

---

[1] «Безнең сиңа күрсәткән роэйәне…» (Коръән, 17:60).

[2] Биредә Муса әфәнде «ләгънәт кыйлынган агач»ны (әш-шәҗәрәт әл-мәлгунә) күздә тота. Бу төшенчә искә алынган 17:60 айәттә телгә алына: «Безнең сиңа күрсәткән роэйәне һәм ләгънәт кыйлынган агачны да кешеләр өчен фетнәдән башка һични итмәгән идек». Биредә пәйгамбәргә күрсәтелгән роэйә белән ләгънәт кыйлынган агач – икесе дә фетнә буларак бәяләнәләр, чөнки Мөхәммәд пәйгамбәр ﷺ бу ике нәрсә турында мөшрикләргә сөйләгәндә, аңардан көлә торган булганнар.

# «Дини мәктәбләр, мәдрәсәләр хакында мөляхәзалар»[1]

Дини мәктәпләребезнең, дини мәдрәсәләребезнең гаять бөек әһәмиятләренә күрә, һәрбер мөселманның игътикадына, вөҗданына ятышлы була алачак кайбер уйларымны биредә тәкъдим итәм.

1) Русия мөселманнарының иң зарури хаҗәтләренең берсе, әлбәттә, башлангыч милли мәктәпләре, дини-гыйльми мәдрәсәләредер. Әүвәлге авыр ысуллы дини мәктәпләребез, дини мәдрәсәләребез төрле халыкларны үз эченә алган зур дәүләт эчендә гасырлар буенча динебезне, милләтебезне, телебезне ничек булса да саклады. Моннан соң мөстәкыйль бер ислам милләте булып тәрәккыять юлларында дәвам итүебез мәсьәләсе бүгенге җиңел ысуллы башлангыч милли мәктәпләребез, ислях кыйлынган дини мәдрәсәләребез бәрәкәте белән генә тәэмин кыйлына алачак.

Өмет итик, фараз итик, Русиядә укыту һәм гомуми, һәм мәҗбүри кыйлына алса, ул очракта безнең милли башлангыч мәктәпләребезнең, безнең дини мәдрәсәләребезнең безнең хакта һәрьяклап әһәмияте янә артачак, мәктәп-мәдрәсә мәсьәләләрен безнең киләчәгебезгә яраклы һәм кирәкле сурәттә хәл итү, тәэмин итү вазифалары да һәрьяклап авыр булачак.

Ак сәхифәләр йөзендә язылган статьяләрнең, маддәләрнең аңлаешлы гыйбарәләренә канәгать итмичә, мәгариф сәясәтләрендә гомумилек һәм җитдилек кәсеп иткән куәтле чараларның ни рәвешле эшләвенә дә баксак, мәктәп сәясәтләрендә руслаштыру ысулларыннан көннәрнең берендә хөкүмәт бәлки

---

[1] Муса Җаруллаһ. Петербургда 1914 сәнә июнь 15–25дә рәсми җәмгыять мөнәсәбәтейлә исляхат әсасләре. Петроград, Типография М-А. Максутова, 1915. Б. 251–257. (Татар теленә тәрҗемә ителеп кыскартылып бирелә).

ваз кичәр дип уйлау тугры булмаса кирәк. Гаять ерак бер ихтимал булса да, фараз итик, мәгариф сәясәтләрендә хөкүмәт руслаштыру ысулларын моннан соң кулланмас, диик. Бу очракта да, мәгариф нәзарәтенең белдеге белән гомуми буларак ачылачак училищеларның, учебный заведенияләрнең программалары Русия мөселманнарының балаларына мөселман татар булу шәрәфе белән тиеш булачак милли, дини тәрбияне канәгатьләндерер кадәр һичбер вакыт тәэмин итә алмаячак. Дини-милли тәрбиябезгә хезмәт итә алачак программаларны хөкүмәтнең гомуми мәктәпләреннән, урта дәрәҗә учебный заведенияләрдән таләп итү мөмкин дә түгел, акыллы да түгел, кирәкле дә түгел.

Гаять ачык, гаять гади бу уйлар кабул кыйлынса, димәк, милли башлангыч мәктәпләремез, дини-гыйльми мәдрәсәләребез һәр хәлдә вә һәрьяклап безнең идарә астында, безнең ихтыярда булырга тиеш.

Мәктәп-мәдрәсәләре хакында Русия мөселманнарының бу күзаллаулары, бөтен Русия мөселманнарының хаклы һәм аларны канәгатьләндерерлек таләпләре буларак, хөкүмәтнең игътибарына берничә мәртәбә тәкъдим ителгән иде <…>

Проектларда, программаларда тәфсилләп язылган таләпләребезнең кыскасы – Русия мөселманнарына бөтен яклары үз ихтыярыбызда булачак башлангыч милли мәктәпләр, дини-гыйльми мәдрәсәләр кирәк.

Рухани идарәләребезгә, мәхәлләләребезгә, мәдрәсәләребезгә кирәк булачак булдыклы галимнәрне әзерләү өчен дә, башлангыч мәктәпләребезгә хаҗәт булачак булдыклы мөгаллимнәрне әзерләү өчен дә, тулы хокуклы киң хөрриятле гыйльми-дини мәдрәсәләрнең үз кулыбызда, үз ихтыярыбызда булуы, әлбәттә, зарурдыр.

Башлангыч мәктәпләр хакында нәшер кыйлынган яңа кагыйдәләр һичбер рәвештә, һичбер вакыт безнең милли башлангыч мәктәпләребезгә килешмәячәк. Министерство белдеге белән әзерләнәчәк программалар дини-гыйльми мәдрәсәләребезнең хаҗәтләрен, максатларын һичбер вакыт үти алмаячак. Безгә мәгълүм бүгенге җирле идарәләрнең инспекторлары-

ның мәктәпләребезгә, дини мәдрәсәләребезгә күзәтү-тикшерү вазифаларында әзерлекләре дә, җитәрлек кадәр компетенцияләре дә юк.

Һәр милләтнең әхлакый хокукының үз ихтыярында булуы зарурдыр. Безнең әхлакый хокукыбыз тулысынча үз ихтыярыбызга тапшырылмыйча, мәктәп-мәдрәсә мәсьәләләре дөрес шәкелдә һичбер вакыт хәл кыйлынмаячак.

2) Ят халык балаларын тәрбия максаты белән хөкүмәт әгәр дә башлангыч мәктәпләр ачса, ислам балалары өчен ачылачак мәктәпләре мөселманнарның дини, мәдәни хаҗәтләренә һәм дә милли үзенчәлекләренә яраклы ысулда оештырылмаячак.

3) <…> авыл мәктәпләрен, авыл тормышына файда китерә алырлык сурәттә оештыру кирәк. «Ике класслы алты еллык мәктәпләр» урынына сельскохозяйственный технический начальный мәктәпләр ачып, халыкның әхлакый вә икътисади хәлләрен бераз ислях итү, әлбәттә, урынлырак. <…>

<…> укыту җәдвәлләрендә дүрт еллык башлангыч мәктәбләр өчен тәгайен кылынган дәресләр: закон божий, рус теле, ана теле, хисап, язу, көй. Алты еллык мәктәпләрдә бу дәресләргә өстәп рус тарихы, география, рәсем, һәндәсәдән башлангыч мәгълүмат биреләсе. Мондый мәктәпләрне тәмамлап чыгачак бала – һәрнәрсәдән: дини тәрбиядән дә, авыл тормышына кирәкле булган һөнәрдән дә тәмам мәхрүм калачак.

4) Ислам балаларын бу заманда тиешле сурәттә тәрбия итү мәсьәләләре гаять авырдыр. Беренчедән, безне канәгатьләндерерлек системалы башлангыч милли мәктәпләребез юк яки аз. Икенчедән, безне канәгатьләндерерлек милли башлангыч мәктәпләребез, бер фараз итик, булса, андый мәктәпләрне биш-алты елда тәмам итәчәк бала бүгенге системага күрә, урта дәрәҗә мәктәпләргә кабул кыйлыну бәхетләреннән мәхрүм калачак; башлангыч милли мәктәпләрне күрмәгән ислам балалары урта дәрәҗә мәктәпләргә бирелсә, милли дини тәрбия шәрәфләреннән тәмам мәхрүм калачак.

Әлеге гаять зур проблемалар хозурында, вакытлы сурәттә, бердәнбер чара бар: урта дәрәҗә мәктәпләрнең әүвәлге сыйныфларына кабул кыйлыну өчен, яшь ягыннан ислам ба-

ларына өстенлек бирелеп, башлангыч милли мәктәпләрне тәмамлаган 12–13 яшьлек балаларны урта мәктәпләрнең әүвәлге сыйныфларына кабул итү; һәм дә урта дәрәҗә мәктәпләрнең һәммә сыйныфларында дин, тел мөгаллимнәре билгеләү. <…>

5) Без, Русия мөселманнары, рухани идарәләребез, милли мәктәпләребез, дини-гыйльми мәдрәсәләребез мәсьәләләрендә һәрвакыт гамьсезлек кыйлабыз. Хөкүмәт сәясәте белән, мәгариф министрлыгы тырышлыгы белән кабул ителгән «Март 31 Правилалары»[1] кебек кагыйдәләр безне уятмаса, дини-милли ихтыяҗларыбыздан без һәрвакыт гафил булачакбыз. Милләтнең гафиллеге, гамьсезлеге хөкүмәтнең һәртөрле чараларына хак бирә, һәр хәрәкәтенә юл ача. Милләт үзе гафил булса, сүлпән булса, хөкүмәтнең чараларына, кагыйдәләренә ризасызлык белдерү хакы милләт кулында калмаячак; вакыт үтеп, ризасызлыгын белдерсә дә игътибар ителмәячәк.

Әхлакый, иҗтимагый, икътисади әхвәлебезне ислях итү вазифасында иң куәтле, иң тугры юл: җиңел ысуллы башлангыч милли мәктәпләребез челтәрен булдыру; Көнбатышның урта дәрәҗә мәктәпләрендә, колледжларында голүм, мәгариф, сәнаигъ храмнарында милләт балаларын тәрбия иттерү. Бу юлдан барсак, мәктәп-мәдрәсәләребезгә – булдыклы мөгаллимнәр, мөдәррисләр; рухани идарәләребезгә, мәхәлләләребезгә – булдыклы галимнәр, мөҗтәһидләр; милли хезмәтләребезгә – вөҗданлы, акыллы хадимнәр; сәяси хәрәкәтләребезгә – куәтле, ышанычлы әйдәп баручылар; әдәби тәрәккыятебезгә олы рухлы, саф илһамлы әдипләр, шагыйрьләр заман кулы белән безгә биреләчәк.

Русия мөселманнарының ислам милләте буларак бәхетләренә, мәдәни бөек бер милләт буларак гыйззәтле хәятләренә иң туры юл бары тик будыр.

---

[1] Халык мәгарифе министры И. Толстой тарафыннан 1906 елның 31 мартында расланып гамәлгә кертелгән «Правила о начальных училищах для инородцев, живущих в восточной и юго-восточной России» дигән документ күздә тотыла.

Кодрәтле, аңлы аталар-аналар үзләренең кызларын, угылларын тәрбия вазифаларында, теләпме, мәҗбүри төстәме, әлбәттә, бу юлда хәрәкәт итәрләр. Ләкин милләт балаларының һәм дә укучыларның күпчелеге фәкыйрьләр. Теләкләре көчле булган ата-аналар үзләренең балаларын тәрбия авырлыкларыннан гаҗиз калыр; ятим балалар тәрбиядән мәхрүм булыр; тәкатьтән тыш авырлыкларга юлыгып, үзенең көче белән, тырышлыгы белән уку юлларында дәвам итүче шәкертләрнең таләбәләрнең сәламәтлекләре харап булып, тәмам югалып, вөҗүдләре, миләре тәмам талчыгып, иң бәрәкәтле була алачак яшь куәтләре тәмам бетеп юкка чыгар.

Нәтиҗәдә, милләт үзләренең өметәреннән мәхрүм калыр, балаларын тәрбия итү теләкләре ата-аналарда калмас; теләкләре булган сәләтле яшь студентларда, балаларда уку кыюлыклары югалыр.

Бу дәһшәтле, гаять хәсрәтле бәла, һәрникадәр гомуми бәла булса да, милләтнең бары тик гамьсезлегеннән, игътибарсызлыгыннан үсеп чыга. Милләтнең гомуми хаҗәтләренә, зарури максатларына игътибар белән карый белә алсак, андый бәлаләрне җиңү чаралары, алымнары, әлбәттә, табылыр.

<…>Үз вакытында мөхтәрәм Рәшид әфәнде, остаз Риза әфәнде түбәндәге гаять зур милли хаҗәтебез хакында акыллы һәм кирәкле чаралар бәян иттеләр: 1) Ислам фәрманы белән фарыз кыйлынган сәдәкаларның кайбер өлешләреннән зур бер фонд тәшкил итеп, теләкләре булган сәләтле студентларны, кызларны Көнбатышның урта һәм югарык мәктәпләрендә тәрбия итү. 2) Тырышлык ияләренең игелекләре, юмартлыклары, мактаулы васыятьләре ярдәме белән зур бер ширкәт фонды тәшкил итеп, мөкаддәс мосхәфләрнең нәшерен монополия кулына алу, алынган керемне ислам балаларын Көнбатыш мәктәпләрендә тәрбия юлларына сарыф итү. 3) Тырышлыгыбыз тагын да зуррак була алса, бер Милләт дәфтәре ачып, гаять зур бәрәкәтле милли фонд оештыру мөмкин.

Һәм мөмкин булган, һәм кирәкле булган бу чараларның бере белән, йа һәммәсе белән туплана алыначак зур капитал – милләт балаларын тәрбия юлларына сарыф кыйлынып, бераз

соңрак башка хаҗәтләребезне канәгатьләндерү юлларына да сарыф кыйлына алыр иде.

Безнең киләчәгебезне тәэмин итәчәк безнең милли өметләребезне тормышака ашырачак чаралар бар исә, бары тик мондый җитди чаралар ашыра алыр; максат кәгъбәләренә ирешүебез бары тик бу юлда була алыр.

## «Шәригать әсасләре» исемле китаптан[1]

Шәригатьнең ике зур чишмәсе, ике чыгынагы бар: 1) берсе – Пәйгамбәрнең сөннәте, 2) икенчесе – Коръән кәрим.

Пәйгамбәрнең сөннәте ул – Шаригъ хәкимнең[2] сүзләре, кыйлган эшләре, күрсәткән ярдәм вә киңәшләре. Пәйгамбәрнең сөннәте, күбесенчә, Коръән кәримнең чагылышы була, Коръән кәримнең күрсәтмәләрен тормышка ашыруның бер рәвеше була. Болай булганда, Пәйгамбәрнең сөннәте Коръән кәримдә кыска гына итеп бирелгән нәрсәләрне тәфсилләп ачып бирә, булган очракта мәшәкатьләрне телгә ала, нечкәлекләрен аңлата, катлаулы урыннарны гадиләштерә: (وَأَنزَلْنَا إِلَيْكَ الْكِتَابَ لِتُبَيِّنَ لِلنَّاسِ مَا نُزِّلَ إِلَيْهِمْ)[3]; (وَمَا أَنزَلْنَا عَلَيْكَ الْكِتَابَ إِلاَّ لِتُبَيِّنَ لَهُمُ الَّذِي اخْتَلَفُواْ فِيهِ وَهُدًى وَرَحْمَةً لِّقَوْمٍ يُؤْمِنُونَ)[4].

Пәйгамбәрнең сөннәте, Коръән кәримнең бәяны булмаса да, шәригать хөкемнәре чыгара ала. Сөннәтнең бу өлеше, аның Коръәндә бәян ителгәннәрне аңлатуы өлешеннән ча-

[1] Чыганак: Муса Җаруллаһ. Шәригать әсасләре. Петроград: Типография М-А. Максутова, 1917. Б.7–13. (Өзек татар теленә тәрҗемә ителде).

[2] Шаригъ хәким – хикмәт иясе булган шәригатьче, ягъни Мөхәммәт пәйгамбәр.

[3] «Кешеләргә иңдерелгәннәрне бәян итүең өчен сиңа Китап иңдердек» (Вә әнзәлна галәйкә-л-китабә ли-түбәййинә…), дигән айәт Коръәндә юк. Әмма моңа охшаш булганы бар: (وَأَنزَلْنَا) (вә әнзәлна иләй-кә әз-зикра ли-түбайййинә…), ягъни: «Кешеләргә иңдерелгәннәрне бәян итүең өчен сиңа Искәртүчене (әз-зикер) иңдердек» (16:44).

[4] «Аларны төрле карашлар ияләре булырга мәҗбүр иткән нәрсәнең ни булуын аңлатып бирүең өчен Без сиңа Китап иңдердек һәм (аны) иман итүче бәндәләргә туры юл күрсәтүче вә мәрхәмәт буларак иңдердек» (Коръән, 16:64).

гыштырмача аз булса да, үз башына аз түгел: (وَمَا آتَاكُمُ الرَّسُولُ فَخُذُوهُ وَمَا نَهَاكُمْ عَنْهُ فَانتَهُوا)[1].

Коръән кәрим ул Мөхәммәт пәйгамбәр (ﷺ) башкарган вазифаның дәлиле булып тора, шәригатьнең тулылыгы һәм нигезе булып тора, ул акыл белән йөрәкнең нурыдыр. Минем шәхси карашыма күрә, Коръән кәрим ул – бөтен барлыкның тәрҗемәседер.

Коръән кәрим Гасыр-ы рисаләттә[2] егерме өч ел дәвамында иңгән. Шәригатьнең барлык кагыйдәләре, гомуми өйрәтүләре, мәңгелек нигезләре тулысынча Мәккәдә иңеп, аның Мәдинәдә иңгән айәт кәримәләре [Мәккәдә иңгәннәрне] камилләштерү иде, киңәйтү иде, кайчакта төгәл итеп билгеләүгә кайтып калган чикләү була иде: (إِنَّ اللهَ يَأْمُرُ بِالْعَدْلِ وَالإِحْسَانِ وَإِيتَاء ذِي الْقُرْبَى وَيَنْهَى عَنِ الْفَحْشَاء وَالْمُنكَرِ وَالْبَغْيِ يَعِظُكُمْ لَعَلَّكُمْ تَذَكَّرُونَ)[2]; (خُذِ الْعَفْوَ وَأْمُرْ بِالْعُرْفِ وَأَعْرِضْ عَنِ الْجَاهِلِينَ)[3], кебек айәт кәримәләр Мәккәдә иңгән иде.

Мәккәдә иңгән айәт кәримәләрдә кешеләрнең игелекле булуларына, тормышның әдәп-тәртип кысаларында баруына, аның мәнфәгатьләренә кагылышлы һәрбер гамәл, һәрбер яхшылык иксез-чиксез рәвештә өйрәтелә иде, аңлатыла иде. Иң камил сурәттәге игелеклелек, яхшылык үтә дә кирәкле булган нәрсә иделәр. Гүзәл әхлакъ, югары әдәп, гаделлек, ихсан[4], турылыклылык кебек нәрсәләр аларга хас булган бөтен максатлар белән таләп ителә иде. Начар була алырлык һәрбер эш бөтен төрләре белән бергә тыелды. Шуңа күрә мөселманнар һәр хосуста кямиллекнең максатын күздә тотып эш иттеләр. Мәсәлән, инфак[5] вазифасы чикләнелмәгән иде. Ул вакытта мөэмин кеше үз тырышлыгы белән, үз ихтыяры белән инфак

[1] «Расүлнең сезгә биргәннәрен алыгыз, ул тыйганнардан читләшегез» (Коръән, 59:7).

[2] Гаср-е рисаләт – Мөхәммәт пәйгамбәрнең (ﷺ) Аллаһ рәсүле вазифасын башкарган еллары.

[3] «Гафу итүчән бул, яхшылык кылырга өндә һәм җаһилләрдән читләш» (Коръән, 7:199).

[4] Ихсан – кече күңелле, мәрхәмәтле булу, игелеклелек.

[5] Инфак – матди чыгымнар тоту.

итә иде. Ул заманда мөэминнәрнең һәрберендә ярдәмчеллек кебек игелекле сыйфат өстенлек итә иде. Ул вакытта тынычлык та, сәламәтлек тә югары дәрәҗәдә иделәр.

Мәдинәдә иңгән айәт кәримәләрдә Мәккә айәт кәримәләрнең нигезләре камиллеккә җиткерелде, киңәйтелде; кайбер хосусларда төгәл билгеләмә бирелү аша кысаларга кертелде. Ләкин бу эш Мәккәдә иңгән айәт кәримәләрдә әйтелгәннәрне нәсех[1] кыйлу рәвешендә түгел, бәлки, киресенчә, рөхсәт юлы белән, киңәйтү юлы белән иде.

Мәсәлән, мөдәфәга[2] мәшругъ булды[3], ләкин гафу юлында сабыр итү яхшырак иде: (وَإِنْ عَاقَبْتُمْ فَعَاقِبُواْ بِمِثْلِ مَا عُوقِبْتُم بِهِ وَلَئِن صَبَرْتُمْ لَهُوَ خَيْرٌ لِّلصَّابِرينَ)[4].

Мәсәлән, матди чыгымнарның төрләре төгәл рәвештә билгеләнде. Иң күбесе биш өлештән гыйбарәт булган инфак дүрт өлешкә калдырылды: 1) биш; 2) бишнең яртысы; 3) биштән дүрт өлеш; 4) биштән сигез өлеш. Әмма чикләнелмәгән инфак кыйлу һаман да рөхсәт ителде, хәтта кирәкле булып калды: (وَيُؤْثِرُونَ عَلَى أَنفُسِهِمْ وَلَوْ كَانَ بِهِمْ خَصَاصَةٌ)[5].

Коръән айәтләренең иңү тәртибенә игътибар итсәк, диннең һәм тормышның төзлешенә, тәртибенә кагылышлы гомуми кагыйдәләр, кирәкле булган нигезләр тулысынча Мәккәдә иңгән, шул төзелешнең, тәртипнең тәфсиле, аңлатылуы, ачыклануы киңәйтелү, камиллеккә ирештерелү юлы белән Мәдинәдә

[1] Нәсех – Коръән гыйлемнәренә караган төшенчә буларак теге яки бу айәт хөкемен башка бер айәт яки хәдис хөкеме белән гамәлдән чыгаруны күздә тота. Муса Бигиев Коръән айәтләрен нәсех кыйлуны кискен рәвештә тәнкыйтьли торган булган. Шуңа күрә биредә нәсех сүзен гамәлдән чыгару дип кенә аңларга кирәк.

[2] Мөдәфәга – биредә кыерсытуга, җәзалауга җавап рәвешендә каршылык күрсәтү.

[3] Мәшругъ булды – рөхсәт ителде, шәригатькә кертелде, законлаштырылды.

[4] «Җәза бирсәгез, үзегезгә бирелгән җәза кадәрендә генә җәзалагыз. Ә инде сабыр итсәгез, болай итү сабырлар өчен тагын да хәерлерәктер» (Коръән, 16:126).

[5] «Хәтта үзләре кыен хәлдә булсалар да, аларның ихтыяҗларын алга куялар» (Коръән, 59:9).

бәян ителде. Мәдинәдә иңгән айәтләр Мәккә айәтләренең аңлатмалары, ачыкламалары булып торалар.

Ислам шәригатендә игътибар үзәгендә тотылган максатлар берничә: 1) динне саклау, 2) җанны саклау, 3) акылны саклау, 4) малны саклау, 5) нәселне саклау, 6) шәрәфне саклау. Әлеге зарури булган максатларның эчтәлеген тәфсилле итеп яки кыскача гына ачыклаган айәт кәримәләр Мәккәдә инде. Динең биш баганасы: 1) иман, 2) саләт[1], 3) зәкят Мәккәдә иңгән айәт кәримәләрейлә бәян ителеп, 4) ураза, 5) хаҗ кебекләре Ибраһим пәйгамбәрнең сөннәте буларак Мәккәдә мәшругъ булды да, шул рәвешле Мәдинә иңгән айәт кәримәләрне кямиллеккә ирештерде. Хәтта Мәдинәдә шәригатькә кертелгән җиһад хөкеме дә Мәккәдә боерылган булып «*яхшылыкны әмер итү һәм яманлыкны тыю*»[2], кебек асыл вазифаның бер тармагы кебек иде.

Ибраһим бин Муса әш-Шатыби хәзрәтләре «Әл-Мөвафәкать»нең 3 нче кисәгендә, 22–23 нче сәхифәләрдә болай дигән: «*Шәригатьнең һәрбер хөкеме Кәрим китапта тулысынча һәм чикләнүсез дәлилләнгән, һәм аның өчен хаслап ни бер канун, ни билге ясалмаган. Ул хөкем акыл тарафыннан кабул ителерлек мәгънәгә иядер, һәм аларның барысы да карар кыйлучының шәхси ихтыярына һәм карамагына тапшырылган. Ошбу үзенчәлек көнкүреш эшләренә кагылышлы очракларда бик тә яхшы күренә. Андыйлар арасында үтәлү өчен әмер ителгән гаделлек вә игелеклелек, гафу итү, сабыр кыйлу, шөкер кыйлудыр; ә тыелганнар арасында золым һәм бозыклык, яманлык һәм буйсынмау, сүздә тормау кебек нәрсәләрдер. Коръән кәримдә катгый (абсолют) буларак*

[1] Саләт – биредә намаз күздә тотыла. Асылда исә саләт (салават) сүзе «бәйләнеш» мәгънәсенә ия, ягъни, саләт ул Аллаһ белән бәйләнештә булудыр. Намаз сүзе мондый мәгънәгә ия түгел, чөнки, беренчедән, намаз – татар һәм башка төрки телләргә фарсы теленнән кергән сүз, икенчедән, аның мәгънәсе «иелү», «баш иеп хөрмәтләү»не белдерә.

[2] Әлеге хөкем Коръәннең: «Арагызда игелеклелек кыйлырга өндәүче һәм начарлыкны тыючы бер өммәт булсын» (3:104), дигән айәтенә кайтып кала.

*карар кыйлынмаган нәрсәләргә килгәндә исә, андыйларның гыйбадәтнең төрле үзенчәлекләренә караган булуын аңларга кирәк. Андый үзенчәлекләр гыйбадәт кыйлырга тиешле булган бәндәнең ихтыярына һәм карар кыйлуына тапшырылмаганнар. Чөнки гыйбадәт кыйлуның ни асылы, ни тышкы күренеше акыл белән хөкем ителә торган нәрсәләр түгелләр. Югарыда искә алынган нәрсәләр гыйбадәт белән азмы-күпме бәйләнештә булган нәрсәләргә карата да дөрестер. Бу хасият үзен гыйбадәт хөкемнәрендә сиздерә һәм Мәдинә-и мөнәүвәрәдә иңдерелгән айәт кәримәләр тарафыннан катгый төстә раслана. Чөнки Мәдинәдә иңдерелгән хөкемнәр аңарчы [Мәккәдә] катгый хөкем рәвешендә иңдерелгән хөкемнәрне теге яки бу шартларга яраклаштыралар. Моннан тыш Мәдинәдә иңдерелгән нәрсәләр элегрәк иңдерелгән төгәл сәбәпләргә карата хөкемнәр бәян итәләр*».

Ягъни, шәригать исламия кеше тормышына кагылышлы илаһи тәгълиматны, илаһи күрсәтмәләрне ике юл белән белдерә: 1) берсе төгәл билгеләмә, катгый күрсәтмә бирү юлы, тәгаенләү юлы; 2) икенчесе төгәл билгеләмә бирмичә генә бәян итү, гомуми төстә аңлату юлыдыр.

Гыйбадәтләр һәм үзгәрешсез хәлдә саклануы таләп ителгән нәрсәләр турында гыйлем бирү хосусларында Шаригъ хәким төгәл билгеләмә бирү юлын сайлый. Андый нәрсәләрнең нигезләрен, шартларын, әдәпләрен тулысынча тәгайен итә. Гыйбадәтләр, исламият сөннәте буларак тапшырылып килә торган гадәтләр – болар һәммәсе дә әләге юл белән өйрәтелгән. Әһле исламның[1] телләрен тәүхид шигаре[2] белән бизәп, йөзләрен бер кыйбла тарафына юнәлдергән исламият һәр җирдә, һәр гасырда булачак мөселманнарга үзләренең

[1] Әһле ислам – ислам динен тотучылар, мөселманнар.

[2] Тәүхид шигаре (гарәп: тәүхид – берләштерү; гарәп.: шигарь – сөрән, лозунг, герб) – илаһның берлеге турындагы тәгълимат, Аллаһның бердәнбер илаһ булуына инану; биредә сүз лә иләһа иллә аллаһу (Аллаһтан башка һичнинди илаһ юктыр), дигән шаһитлык сүзе (кәлимә-и шәһадәт; шәһадәт), гуаһлык итү, (урысчасы: свидетельствование) турында бара.

дәрәҗәләрен аңлаулары өчен, аларны рухландыру өчен булса кирәк, дини һәм милли асылларын саклауга кагылышлы кагыйдәләрне төгәл итеп билгеләү алымы ярдәмендә күрсәткән.

Гади эшләрдә, ягъни дәүләттә гаделлекне саклау юлларына, иҗтимагый яшәештә тәртип, төзеклелек һәм куркынычсызлык хосусларына, көндәлек тормышны тәртипле вә төзек рәвештә алып бару чараларына, гаилә хәлләренә, әхлак тәрбиясенә кагылышлы гыйлем бирү хосусларында Шаригъ хәким төгәл бәяләмә бирмәү алымын өстен күргән. Шаригъ хәким бу өлкәләрдә аек акыл дәлилләренә, кешенең сәламәт табигатенә хас булган зәвыкка, күз белән күрелгән нәрсәләргә дөрес бәя бирә алуның җитәкчелегенә таянып эш итүне җитәрлек дип санаган. Чыннан да, үзләренә файда китерә ала торган нәрсәләргә карата кешеләрнең битараф булмауларын, үзләренә шундый нәрсәләрне теләүләрен, һәртөрле зарарлардан, бозыклыклардан табигый сурәттә чирканууларын исәпкә алганда, сәламәт акыл белән сәламәт йөрәк андый нәрсәләрдә, әлбәттә, юл күрсәтүче, әйдәп баручы була. Дәүләттә – гаделлекнең, иҗтимагый яшәештә – тәртипнең, йортларда – төзеклелекнең, гаиләдә – гүзәл мөнәсәбәтләрнең, әхлак тәрбиясенең, ягъни искә алынган нәрсәләрнең яхшы күренеш булулары һәм кирәкле булулары акылның үзенә, табигый тойгылар кушуы белән, әлбәттә, мәгълүм була ала. Һәм дә милләтләрнең тумыштан бирелгән психик табигатьләре, тарихи дәверләрнең мәнфәгатьләре, географик урыннарның үзенчәлекләре, ни дисәң дә, һәрьяклап төрле була. Шулай булгач, һәр милләт үзенең яшәгән дәверенә, яшәешенең табигый шартларына һәм климатына, үзенең табигый темпераментына күрә, тәртип-интизамны тәэмин итә торган канун вә кагыйдәләрне, гаделлек принципларын, идарә итү нигезләрен үз акылы белән, үз тәҗрибәсе белән, үз ихтыяры белән сайлый.

Һәр милләткә, һәр җиргә, һәр вакытка килеп киткән санап бетергесез пәйгамбәрләрнең, хикмәт аяләренең багулары белән, гомуми саны бары тик Аллаһ хәзрәтләренең Үзенә мәгълүм булган гасырлар дәвамында тәрбия кыйлынып, адәм

баласының акылы җитлегү дәрәҗәсенә, балигъ булу мәртәбәсенә иреште.

Шул вакытта иң соңгы мөгаллим буларак, ислам пәйгамбәре Мөхәммәд, галәйһи-с-саләт вә-с-сәлам, хәзрәтләре күнделде.

Акылның моннан соң арадашчыларның химаясеннән, вәлиләрнең[1] тәрбиясеннән азат булачагы Китап һәм хикмәтнең иң бөек мөгаллиме булган Шаригъ кәбир[2] *нәбий-е ислам*[3] *хатим әл-әнбия*[4] Мөхәммәт Әминнең[5] үтемле теле белән Мәдинәдә яши башлавының беренче елларында: (وَلَكِن رَّسُولَ اللَّهِ وَخَاتَمَ النَّبِيِّينَ)[6], дигән мөбарәк гыйбарә белән бөтен кешелек дөньясына игълан ителде.

Кешелек дөньясы өчен илаһилык күкләреннән, гыйззәт тәхетеннән иңгән шатлыклы хәбәрнең иң олысы – нәкъ менә шушы илаһи сөенчедер. Әлеге сөенче белән, бер яктан, акылның җитлеккән булуы, аның булдыклылыгы, икенче яктан, аның арадашчылар тарафыннан химая ителгән чактагы хокуксызлыгыннан, вәлиләр тәрбиясендә шәкертлектән котылуы әнә шул «хатәм ән-нәбиййин»[7], дигән исемнең мөһере белән расланды.

---

[1] Вәлиләр – әүлияләр, үзләренең Аллаһка бирелгәнлекләре, диндарлыклары, тәквалыклары, пакьлекләре, рухи югарылыклары сәбәпле, изгеләр буларак танылган кешеләр.

[2] Шаригъ кәбир – шәригать хөкемнәрен булдыручы иң бөек кеше яки туры юлга күндерүче иң бөек кеше, ягъни Мөхәммәт пәйгамбәр (ﷺ).

[3] Нәбий-е ислам – ислам пәйгамбәре.

[4] Хатим әл-әнбия – пәйгамбәрләрнең мөһере.

[5] Мөхәммәт Әмин (Мөхәммәт әл-Әмин) – Әмин, ягъни Ышанычлы, Турылыклы, Әманәтле дигән мәртәбәле кушамат Мөхәммәт пәйгамбәргә аның югары әхлакый сыйфатлары өчен шул заман халкы, Мәккә әһеле тарафыннан бирелгән була. Әлеге исемгә лаек булган чагында Мөхәммәт Аллаһ илчесе вазифаларын әле башкара башламаган була, беренче вәхи аңа әле килмәгән була.

[6] «Ул нибары Аллаһның илчесе һәм пәйгамбәрләрнең мөһере» (Коръән, 33:40).

[7] хатәм ән-нәбиййин – пәйгамбәрләрнең мөһере.

Пәйгамбәрлекнең тәмамлануы – акылның җитлегү, аңлылык, булдыклылык, мөстәкыйльлек, ихтыяр мәртәбәләренә ирешүе димәктер.

Шуңа күрә, Коръән кәрим кешеләрнең барысына да мөрәҗәгать иткәндә – күзләре ачык, акыллары кямил, аңнары уяу булган кешеләргә хикмәт ияләре булган бөекләрнең васыятьләре рәвешендә мөрәҗәгать итә: гаделлек, төзеклелек, яхшылык, игелеклелек, гафу кебек абсолют һәм киң тәгъбирләр белән кешеләрне гаделлек һәм турылыклылык юлларына юнәлтә; золым, бозыклык, дошманлык, хыянәт кебек гомуми яманлыклар даирәсенә керә алган һәр эштән, һәр сүздән чиркандыра һәм аларны ясак кыйла; вакчылланудан, вак-төяк нәрсәләрдә төпченүдән читләштерә.

Коръән кәримнең таләпләр һәм тыюлар турындагы кыска яки гомуми мәгънәле сүзләр белән канәгатьләнүе Шаригъ хәкимнең кешенең тәрбия кыйлынган акылына, тәҗрибә туплаган ихтыярына таянуына кайтып кала.

Кешенең үзе өчен игелек тели торган табигате, яхшыны яманнан, зарарларны файдалардан аера белә торган сәламәт зәвыгы, хәерле нәрсәләрне начар нәрсәләрдән тәгаен кыйла ала торган аңы, һәр хосуста иң яхшыларны сайлый ала торган ихтыяры – илаһи кайгырту, багу кулы белән тапшырылган бу матур сыйфатларның һәммәсе дә кешедә булдырылып, гасырлар дәвамында тәрбия кыйлындыктан соң, Шаригъ кәрим Аллаһ Рабб әл-галәмин[1] хәзрәтләренең үзенә ышаныч белдерүен кеше, әлбәттә, кәсеп иткәндер. Моны кешенең шәрәф-мәртәбә иясе булуы, киң вә яхшы күңелле, ачык чырайлы зат булуы, Шаригъ кәримнең хикмәте таләп итә. Акыл белән ихтыярның эшчәнлеге дә моны таләп итә.

Эзләнү, табу, казану кешенең акылын, теләген, ихтыярын тәрбияли. Һәрнәрсә әзерләнеп куелган булса иде, кеше ялкау булыр иде; һәрнәрсә бәян ителгән булса иде, акылның

---

[1] Рабб әл-галәмин – барлык кешеләрнең, яки бихисап терек галәмнәрнең тәрбиячесе, багучысы, җитлектерүчесе булган Аллаһ Тәгалә исемнәренең берсе, ягъни Галәмнәрнең раббысы.

әһәмияте калмас иде, кешенең ихтыяры эшлекле, хәрәкәтчән булмас иде.

Үзенең тормышы өчен кирәк булган азык-төлек, кием-салым, торыр урын кебек хаҗәтләрен кеше ничек эзләп тапса, аның мәдәнияте өчен кирәкле булган чараларны, кануннарны да ул шулай эзләр, шулай табар. Беренчесе – табигать хәзинәләреннән, икенчесе тарих калдыкларыннан, Коръән кәримнең айәт кәримәләреннән, пәйгамбәрләрнең, хикмәт ияләренең сабакларыннан эзләнә һәм табыла. Ул беренчел табигый хаҗәтләрен казанганда файдалыны зарарлыдан ничек аерган булса, әлеге мәдәни хаҗәтләре яссылыгында үзенең мәнфәгатьләренә туры килгән нәрсәләрне начар нәрсәләрдән шул рәвешле аралый.

Шуңа күрә, аңлы булу, аек акыллы булу дәрәҗәләренә ирешкән адәм тәмам җитлекте дә, җир йөзендә Аллаһның хәлифәсе ителде. Хилафәт[1] шәрәфе – бер олуг казаныш иде, ягъни табигать мәктәпләрендә, иҗтимагый яшәеш көллиятләрендә дәрес укып имтихан тапшырган адәм балаларына олы бүләк рәвешендә бирелгән «өстенлек» иде, «яхшырту» иде, «һәдия» иде; хокук белгече булуны раслаучы, шәригъләк дипломы иде.

Коръән кәрим, үзенең һәр айәт кәримәсендә булмаса да, әлбәттә, һәр сәхифәсендә, кешенең карашын, игътибарын галәм сәхифәләрендә илаһи кодрәт каләме белән язылган табигать галәмәтләренә һәм дә әүвәлге өммәтләрнең тарих сәхифәләрендә илаһи гаделлек каләме белән язылган җәмгыятькә кагылышлы айәтләренә юнәлдергән.

Кеше бөтен булган мәгълүматны әлеге ике бөек дәфтәрдән: табигать дәфтәре белән җәмгыятъ дәфтәреннән ала. Бу ике бөек дәфтәрнең һәр сәхифәсе һәр кешенең каршында ачыктыр. Ул дәфтәрләрнең берсеннән кеше – бөтен гыйлемнәрне, икенчесеннән яшәеш хокукларын, вазифаларын, әдәпләрен өйрәнә. Шуңа күрә, Коръән кәрим кешенең карашын, аның игътибарын галәм сәхифәләренә дә, иҗтимагый тормыш сә-

[1] Хилафәт – Аллаһы тәгаләнең Адәмгә Үз ышанычын белдереп тапшырылган яшәеш тәртибе, хәлифәлек.

хифәләренә дә юнәлткән. Һәрберсеннән нинди дә булса файда алуы өчен, нинди дә булса нәтиҗәгә килүе өчен. Шуңа күрә, диннең нигезен тәшкил иткән чыганакларның, ягъни Коръән кәрим белән Сөннәтнең дәлилләре кебек, тарихның шәһадәте дә могътәбәрдер; Шаригъның таләбе кебек, акылның да, җәмгыятьнең дә таләбе могътәбәрдер. Кешенең акылы фикерләү ярдәмендә носус шәргыядән[1] Шаригъ кәримнең тормышка ашырырга теләгән нәрсәләрен, аның максатларын аңлап алып, аларны нәтиҗә буларак чыгара белсә, тарихи шаһитлардан Халикъ хәкимнең[2] максатларын, әлбәттә, чыгара ала. Шуңа күрә, фикъһы гыйлемендә фикъһының осуль вә алымнары, ягъни фикъһы методологиясенең теоретик һәм практик нигезләре игътибар үзәгенә куелган икән, иҗтимагый яшәешнең хәлләре һәм вазгыятьләре, тарихта була торган вакыйгалар һәм гыйбрәтләр дә шул рәвешле игътибар үзәгенә куелырга тиешләр. Шәригать хөкемнәрен булдыруның асылын тәшкил иткән осульләр хокукларның чыганаклары булган Китап, Сөннәт, иҗмагъ[3], кыяс[4] кебек рөкеннәр[5] белән генә чикләнә алмый. Әлеге дүрт чыганак фикъһы методологиясенең теоретик һәм практик нигезләрен тәшкил иткән кебек, иҗтимагый яшәештә була торган хәлләр дә, тарихның

---

[1] носус шәргыя – шәригатьнең язма чыганаклары, ягъни Коръән кәрим белән пәйгамбәрнең Сөннәте.

[2] Халикъ хәким – бар нәрсәне барлыкка китерүче хикмәт иясе (халык кыйлучы, яралтучы) булган Аллаһ Тәгалә.

[3] иҗмагъ (килешү) – фәкыйһларның, ягъни дин белгечләренең нинди дә булса мәсьәләнең чишелешенә карата уртак фикергә килүләре, килешү, консенсус. Иҗмагъ шәригать хөкемнәре чыганакларының берсе булып тора.

[4] кыйас (чагыштыру, үлчәү) – нинди дә булса мәсьәләнең чишелешен табар өчен фәкыйһларның ул мәсьәләне тәшкил иткән хәлне аннан алда булган охшаш хәлләр белән чагыштыру алымын кулланулары. Кыйас алымы шәригать хөкемнәре чыганакларының берсе булып тора.

[5] рөкен – терәк, багана, субай, нигез. Биредә рөкен төшенчәсе Коръән, Сөннәт, иҗмагъ, кыйас кебек шәригать нигезләре мәгънәсендә кулланылган.

гыйбрәтләре дә фикъһы методологиясенең теоретик һәм практик нигезләре буларак кабул ителергә тиеш.

Хәким мотлак[1] үзенең хикмәте белән галәм галәмәтләрен, тирә-як дөнья айәтләрен кешеләрнең күзләре, акыллары каршына игътибар өчен урнаштырган икән, ул галәмәтләрдән, ул айәтләрдән файдалануны, нәтиҗәләр чыгаруны үзенең сүзләре белән, әлбәттә, тыймый. Юкса, Шаригъ хәким үзенә үзе каршы килгән булыр иде.

Коръән кәримнең һәм исламиятнең мәңгелеге, гомумилеге, һәрнәрсәне үз эченә алуы тик шушы нәрсәгә кайтып кала: исламиятнең кешелек дөньясының бөтен мәсълихәтләренә, мәдәниятнең һәрбер хәленә туры килүе дә, җавап бирүе дә аның бары тик әлеге фазыйләтеннән[2] гыйбарәт.

---

[1] Хәким мотлак – чиксез вә камил хикмәт иясе булган Аллаһы Тәгалә.

[2] фазыйләт – игелекле эш, югары дәрәҗәдәге яхшылык, мактаулы сыйфат.

# «Бүгенге мөһим хаҗәтләргә күрә чараһ була алачак маддәләр»[1]

39) Мөселман руханиларының мөттәһәмнәрен[2] мәхкәмәләр хозурында химая итү өчен, Диния назарәте чыгымнары исәбенә бер һәйәт мөхамийә[3] булдырылыр.

Бүгенге хадисәләргә күрә, бүгенге фетнәләргә күрә, гаять зарур, гаять әһәмиятле зур бер тәдбирдер.

40) Диния назарәте хозурында хокук мөшавире[4], ягъни юрисконсульт булдырылыр. Назарәт мәсълихәтләрен мөдәфәга[5] итәр; Назарәт мөзакәрәләрендә[6], Назарәт карарларында дәүләт кануны ноктасыннан мөшәвәрәт[7] бирер.

41) Хөкүмәт шөгъбәләренең[8], дәүләт идарәләренең һәрберенең җәридәләрен, мәҗәлләләрен[9], нәшриятләрен Диния назарәте, әлбәттә, алып; сәясәт, мәгълүмат, заман хәлләре турында һәрвакыт һәр хосуста хәбәрдар булып торыр. Диннәргә, мөселманнарга, шәрык мәсьәләләренә кагылышлы хөкүмәтнең һәммә декретларын, һәммә карарларын имамнарга, руханиларга һәрвакыт бәян итәр, ийзах[10] итәр, тәблигъ[11] итәр.

---

[1] Чыганак: Җаруллаһ, Муса. Ислам милләтләренә дини, әдәби, иҗтимагый, сәйәси мәсьәләләр тәдбирләр хакъкында. Берлин, 1923. Б.44–53, 81–84. (Татар теленә тәрҗемә ителде).

[2] мөттәһәм – гаепләнелгән; шикләнелгән; хөкемгә тартылган.

[3] һәйәт мөхамия – яклаучылар оешмасы; адвокатлар коллегиясе.

[4] мөшавир – киңәшче; киңәш итүче.

[5] мөдәфәга – каршы тору, каршылык күрсәтү; бирешмәү; иммунитет.

[6] мөзакәрә – фикер алышу; сөйләшеп утыру; сохбәт кору.

[7] мөшәвәрәт – киңәш, консультация.

[8] шөгъбә – бүлек; бүлекчә; тармак.

[9] мәҗәллә – журнал.

[10] ийзах – ачыклык кертү; ачыклау, аңлату.

[11] тәблигъ – җиткерү; ирештерү.

Заманның гадәттән тыш әһәмиятләренә күрә, бу тәдбир, һәрхәлдә, мөфид, бәлки, һәрхәлдә, зарур бер тәдбирдер. Назарәт диния әгъзаларында бераз һиммәт[1], бераз әһелият; яхуд бераз[2] иман булса иде; мәктәп мөгаллимнәре, мәхәллә имамнары васитасы белән Русия мөселманнарына һәрвакыт яхшы мәгълүмат, куәтле бер хәрәкәт бирә алыр иде.

42) Диния назарәте үзенә махсус зур бер матбага тәэсис итәр. Дини, әдәби, гыйльми китапларны бастырып Русия мөселманнары арасында нәшер[3] итәр.

43) Диния назарәте вакытлы бер мәҗәллә нәшер итәр. Назарәтнең карарларын, хисапларын, хәбәрләрен, игъланнарын, тәдбирләрен, руханиларның һәм таләбәләрнең зәвыкларына мөнасиб мәгълүматларны дәреҗ[4] итеп, Русия мөселманнарының мәсълихәтләрен һәм дә дини хаҗәтләрен тәэмин итү юлында мәҗәллә хезмәт итәр.

44) Фәхеш кебек, мөскират[5] кебек мөфсид[6] мөһлик хәрамнәрнең һәрбере [Диния назарәте тарафыннан] мөмкин юлларның, мөәссир[7] чараларның һәрбере белән тәмам мәныг кыйлынып; мөселманнарның хәят әдәбияләрен, дини идарәләрне, мәхәллә руханиларын, минбәрләрне һәрвакыт назарәт итәр.

Бу вазифа һәрвакыт руханиларның олы әһәмиятле вазифалары иде. Бүгенге хөррият көннәрендә әдәби-әхлакый инкыйлаб көннәрендә, сифилис кеби, алкүъүллек[8] кебек мөһлик

[1] һиммәт – тырышлык; эшләгән эшенең чын мәгънәдә мәгънәсен белү.

[2] Диния назарәтенең әгъзалары, милләт мәҗлесе тарафындан интихаб иделмеш; динләрендә милләтләрендә гаять салабәтле зәват кирамдыр. Бунын ичүн бунлари имансызлыклә төһмәт итмәк әгърас шәхсия ичүн кулланылән фәкать уфак сәясәтчелекдер. Мөсаххих

[3] нәшер – кеше арасында тарату; белрерү, чәчү.

[4] дәреҗ – теркәү.

[5] мөскират – исерткеч матдәләр (алкоголь, наркотиклар).

[6] мөфсид, мөфсидә – бозыклык; начарлык; яманлык.

[7] мөәссир – тәэсир итүче; нәтиҗәле.

[8] алкүъүллек – эчкечелек, алкоголизм.

хәстәлекләрнең тизлек арада дәһшәтле йогулары дәкыйкаларында, бу тәдбирнең әһәмияте кат-кат артты.

Исламият әдәпләренә карата хөрмәтләре булган ислам руханилары бүгенге вазифаларын тәкъдир итеп[1] хәрәкәт итсәләр, иҗтиһад итсәләр, яхшы булыр иде. Аталарга да, аналарга да җәмәгать хадимнәренә дә милләтнең раһбәрләренә дә бу хосусларда тәдбирләр күрү, әлбәттә, бүген инде зарурдыр.

45) [2] Халыкның рухани әдәби гызаларына[3] җамигъларның мөкаддәс минбәрләре йегянә мәнбәгъ булуы җиһәте белән, Диния назарәте җамигъларның, мәсҗедләрнең михрабларын, минбәрләрен ислях итү, ихъйа[4] итү вазифаларына мөмкин юлларның һәрбере белән сәгый[5] итәр.

Минбәрләр ихъйа кыйлыныр исә, әһле исламның вөҗүде җанланыр, миләре сафланыр; иманнары нурланыр; калебләре җәсарәт[6] алыр.

46) Бүгенге мөхарәбә нәтиҗәләре, бүгенге инкыйлаб дәһшәтләре безнең һәммә кимчелекләребезне тәмам ачык итеп, безгә күрсәтте. Иң олы гөнаһыбыз, иң зур кусурыбыз[7]: фәннәр юклык, сәнагатьләр юклык, мәктәпләр юклык икътисад җиһәтеннән, бәлки һәрҗиһәттән фәкыйрьлек һәм зәгыйфьлек.

Моннан соң әдәби, иҗтимагый, икътисади, дини әхвәлебезне ислях итә алсак, [моның] иң мөфид, иң тугры юлы:

б) асан[8] ысуллы ибтидаъи милли мәктәпләребезне тәгъмим[9] итү,

---

[1] тәкъдир итеп – аңлап.

[2] 45нче маддә асыл нөсхәдә, мөгаен, типографик хата булуы йөзеннән, куелмаган.

[3] гыза – азык; ризык.

[4] ихъйа – терелтү, тергезү; яшәеш бирү.

[5] сәгый – тырышу.

[6] җәсарәт – кыюлык; батырлык.

[7] кусур – җитешсезлек, кимчелек; ялкаулык.

[8] асан – җиңел, уңай, җайлы.

[9] тәгъмим – барлык җиргә кертү, тарату; гомуми итү.

ж) мәдәният дөньясының урта мәктәпләрендә, зур көллияләрендә[1] голүм, мәгариф, сәнаигъ, һөнәр хәзинәләрендә милләт балаларын тәрбия итдереп, икътисад гамәлләренә, хәят юлларына, дәүләт идарәләренә милләт балаларын әзерләү.

Бу юлда хәрәкәт итсәк, мәктәп-мәдрәсәләребезгә моктәдир[2] мөгаллимнәр, моктәдир мәдрәсәләр; мәхәлләләребезгә, рухани идарәләребезгә моктәдир галимнәр, моктәдир мөҗтәһидләр[3], милли хезмәтләребезгә вөҗданлы, бәсыйрәтле[4] хадимнәр; сәяси хәрәкәтләребезгә куәтле, сәбатлы[5] раһбәрләр; әдәби тәрәккъыятебезгә олы рухлы, саф илһамлы, киң хыяллы әдипләр вә шагыйрьләр – заман кулы белән безгә ихсан[6] кыйлыныр.

Мөгаллимнәр җиһәте белән дә милләтнең бүгенге хәлләре гаять фәнадер[7]. Әдәпле, әһелиятле, моктәдир мөгаллим вә мөгаллимәләрдән тәмам мәхрүм булуыбыз бүген гаять ачык заһир[8] булды. Милли хезмәт мәйданнарында вөҗданлы һәм бәсыйрәтле хадимнәребез дә гаять аз, сәяси хәрәкәт юлларында куәтле, сәбатлы раһбәрләребез дә гаять аз. Мөҗаһәдә[9] сыйныфларында җәсарәтле, иманлы мөҗтәһидләребез дә юк.

Мөхарәбә нәтиҗәләре, инкыйлаб туфаннары күзләребезне ачты, бөтен кусурыбызны күзләребез алдына бастырды. Бүген безгә җөмһүрият хокуклары, автономия ихтыярлары бирелде, дияйек. Ләкин мәйданда эш адәмнәре юк. Моны инде игътираф итәек. Шуңа күрә:

---

[1] көллия – 1) бөтенлек; тулылык; 2) урта махсус белем бирү йорты, колледж.

[2] моктәдир – көчле; көче җитүче; сәләтле, булдыра алырлык.

[3] мөҗтәһид – дини гыйлемнәр белән эш итүче акыл иясе.

[4] бәсыйрәт – күзе ачык булу; күренешләрнең асылын күрә алу сыйфаты.

[5] сәбат – фикердә эштә нык торучанлык; чыдамлылык, ныклык, какшамаслылык.

[6] ихсан – бирү; тапшыру; ярдәмчеллек; изгелек кылу; яхшылык.

[7] фәна – начар, яман.

[8] заһир – ачык, күренеп торучы; тышкы.

[9] мөҗаһәдә – тырышу, көч кую; дин өчен көрәшү.

47) Мәдәният дөньясының голүм, мәгариф, сәнаигъ, һөнәр мәктәпләрендә, зур көллияләрендә милләт балаларын тәрбия иттереп; икътисад гамәлләренә хәят юлларына, дәүләт идарәләренә милләтебез балаларын әзерләү бүген иң беренче вазифа булды.

Бүгенге зарур вазифаларның иң зурысы буларак, милләт бу хакта сәгый итәр. Моңа махсус сәрмая тәшкил итәр, тәдбирләрен күрер; юлларыны тәэмин итәр. Русия мөселманнары да, Төркестан мөселманнары да, башкорт-казакъ мөселманнары да бу хосуста олы җитдилек белән, газем[1] белән хәрәкәт итәрләр.

48) Ислам балаларын әмин монсыйф[2] бер мөслим, җәсарәтле куәтле бер төрек, мөҗтәһид бер инсан кыйлмак юлында тәрбия ляземдер. Ягъни, ислам балаларының һәм рухларын да, һәм акылларыны да тәрбия кыйлу зарурдыр.

Инсаният мәсълихәтләре дә, исламият мәсълихәтләре дә, һәрхәлдә, һәрҗирдә дәүләт һәм мәдәният мәсълихәтләре шуны таләп итә.

Мәгариф назарәтләренең мәгърифәте белән гомуми буларак тәртип кыйлыначак мәктәп, мәдрәсә, көллият программалары Русия мөселманнарының балаларына мөселман төрек булу шәрәфе белән булачак милли, дини, әдәби, мәдәни тәрбияләрне канәгать булыр кадәр төстә һичбер вакыт тәэмин итә алмас. Мондый программаларны хөкүмәтнең дә, дәүләтнең дә гомуми мәктәпләрендә таләб итү мөмкин түгел, мәгъкуль дә түгел, матлуб[3] да түгел.

Ак сәхифәләр йөзендәге статьяларның, маддәләрнең бәлягатьле гыйбарәләренә канәгать итмичә, мәгариф сәясәтләрендә гомумият һәм җитдилек кәсеб иткән куәтле тәдбирләрнең фигълият[4] җиһәтләренә дә баксак, бу бәян бәлки кабул кыйлыныр. Шуңа күрә:

---

[1] газем – тәвәккәллек; катгый ният; нык омтылыш.

[2] монсыйф – инсафлы, турылыклы, гадел.

[3] матлуб – теләнгән, таләп ителгән нәрсә.

[4] фигълият – эшләнгән эш; эшчәнлек.

49) Милли ибтидаи мәктәпләребезнең, дини-гыйльми мәдрәсәләребезнең һәрхәлдә, һәрҗирдә, һәрьяклап безнең идарәдә, безнең ихтыярда булулары, әлбәттә, зарурдыр.

Хакъканиятле[1] канәгатьле таләбәләре буларак, Русия мөселманнары моны гарыз итәр иде. Моннан соң да, әлбәттә, һәрвакыт таләп идәр.

50) Ислам балаларын матлуб һәм мәгъкуль сурәттә тәрбия итү, тәрбия иттерү Русиядә, бәлки һәрҗирдә, гаять авыр иде. Бүген инде тагын да авырайды. Авырлыгы нисбәтендә әһәмияте дә кат-кат артты.

Мәктәп-мәдрәсә мәсьәләләрендә бөтен куәт белән сәгый итмәк милләтнең дә, Назарәтнең дә, һәм дә һәммә руханиларның да бүген инде зур вазифаларыдыр, бәлки Назарәтнең бүген ялңыз бер вазифасы, ялңыз бу вазифасы калды дисәк дә, тугры булыр.

15) Бүген безнең, бәлки бөтен әһле исламның ике зарур хаҗәте бар: 1) мәдәният дөньясының бөтен голүмнәре, фөнүннәре[2], санаигълары, һөнәрләре, 2) голүм әдәбиясе[3], голүм диниясе.

Әүвәлге зарурәт, әүвәлге хаҗәт мәдәният дөньясының мәктәпләрендә, әлбәттә, табылыр. Мәдәният мәктәпләренең ишекләре дә ислам балаларына моннан соң бәлки һәрвакыт һәрҗирдә ачык булыр, ачык калыр. Ләкин исламиятнең голүм әдәбиясе, голүм диниясе мәдәният мәктәпләренең һичберендә юк иде, моннан соң да булмаячак; бүген Төркиядә дә, Төркестанда да, Гарәпстанда да юк. Иҗтиһад итсәк, [иҗтиһад] юлы белән хәрәкәт итсәк, исламиятнең бөтен голүм әдәбиясе, бөтен голүм диниясе ялңыз ислам дөньясында, үзебездә – ялңыз Русиядә булыр. (?)[4]

52) Исламның голүм әдәбияләрен мөмкин булган юлларның һәрбере белән тарату өчен, Русиядә әһле гыйлемнән бү-

---

[1] хакъканият – чынлык; турылыклылык; ышанычлы булу.

[2] фөнүн – фәннәр.

[3] голүм әдәбия – ислам әхлагына караган белем, гыйлемнәр.

[4] Сорау билгесе китапның мөхәррире Гаяз Исхакый тарафыннан куелган.

ген фидаи[1] бер гыйльми һәйәт тәшкил кыйлыныр. Үзенең рагъбәте белән, үзенең һиммәте белән бөтен зәхмәтләрен[2] илтизам[3] итәчәк бу фидаи гыйльми һәйәт голүм әдәбия, голүм диния тәдрисаты[4] белән мәшгуль булып; голүм әдәбия, голүм диния рагыйбләренә[5], мөгаллимнәргә, имамнарга, хатыйбларга мәҗҗанән[6], халисан[7] ли-вәҗеһе Аллаһ[8] голүм әдәбия, голүм диния дәресләрен бирер.

Мәдрәсә биналары хаҗәт түгел, җамигъларның бере кяфидер[9]; яңа программалар хаҗәт түгел, әүвәлге гасырларның дәресләре кебек фән тәмам итмәк[10] усульләре[11] дәһа зиядә[12] мөфид була алыр.

53) Мәдәният дөньясының голүм, фөнүн, санаигъ мәктәпләрендә милләт балаларын тәрбия иттереп, икътисад гамәлләренә, хәйат юлларына, дәүләт идарәләренә милләт балаларын әзерләү хосусларында лязем булачак тәдбирләрнең һәрберенә бу фидаи гыйльми һәйәт бүген, би лә тәэхир[13], сөлүк[14] итәр, милли, иҗтимагый, әдәби тәрәккыятебез хәрәкәтләрендә безгә лязем булачак әдәп гаскәрен бөтен милләтнең куәте белән, бөтен милләтнең иганәсе белән, бу гыйльми һәйәт тәшкил итә.

---

[1] фидаи – фидакяр; нинди дә булса эшне үз-үзен аямыйча бирелеп эшләүче; максатка ирешер өчен үзен корбан итүче.

[2] зәхмәт – кыенлык, уңайсызлык, авырлык, мәшәкать.

[3] илтизам – йөкләү; үз өстенә алу, мәҗбүр итү.

[4] тәдрисат – укыту; дәрес бирү.

[5] рагыйб – кызыксынучы; теләүче, эстәүче.

[6] мәҗҗанән – түләүсез; бушлай.

[7] халисан – ихластан; ихлас сурәттә.

[8] ли-вәҗеһе Аллаһ – Аллаһның йөзе (ягъни ризалыгы) өчен.

[9] кяфи – җитәрлек, тиешле кадәр.

[10] фән тәмам итмәк – фәнне җиренә җиткереп өйрәнү.

[11] усуль – тамырлар; нигезләр.

[12] дәһа зиядә – күбрәк, тагын да күбрәк.

[13] би лә тәэхир – кичектермәстән; кичектерүсез; соңармастан.

[14] сөлүк – керү, керешү; бер эшкә керешү.

Сәяси фөтүхат[1] өчен сугыш гаскәре безгә – Русия мөселманнарына – бүген, бәлки, кирәк түгелдер, ләкин әдәби фөтүхат өчен әдәп гаскәренең булуы бүген, әлбәттә, безнең зарури бер хаҗәтебездер.

54) Мәктәп-мәдрәсә мәсьәләсе, мөгаллим-мөгаллимәләр мәсьәләсе бүген инде фәукыл-гайә[2] олы һәм дә гаять авыр бер мәсьәлә булды. Мәктәп-мәдрәсәләрнең программалары хакында бераз исә дә ихтыярыбыз бар иде. Бүген инде калмады. Мөгаллим-мөгаллимәләребезне әзерләү өчен, имамнарыбызны, хатыйбларыбызны, мәдрәсәләребезне әзерләү өчен, мәдрәсәләребез бар иде. Бүген һәммәсе ябылды.

Мәдәният мәктәпләрендә, көллияләрендә балаларыбызны тәрбия итә торыр исәк, голүм әдәбия, голүм исламия бер гыйльми һәйәт һиммәте беләнә нәшер кыйлына торырлар исә, милли-дини ихтыяҗларыбыз берничә ел эчендә тәэмин кыйлына башланыр иде.

Яхшы мәктәп, яхшы әдәбият, яхшы тәрбия, яхшы дин безгә лязем исә, бу юлларда иҗтиһад итү, әлбәттә, лязем улур; зарур булыр.

Бу маддәләрдә бәян кыйлынган тәдбирләр – бүген күрелергә мөмкин булган һәм иң мөфид булган тәдбирләрдер.

55) Мәдәният дөньясының мәктәпләрендә балаларыбызны тәрбия итү мәсьәләсенә нисбәтән бу бөек мәҗлестә мөзакәрә ителергә тиешле гаять зур бер мәсьәлә бар: ят халкының зур мәктәпләрендә, куәтле мохитларында тәрбияләрен тәкмил[3] итүче гүзәл кызларыбызның бәгъзылары[4] соңгы көннәрдә ислам гаиләләреннән качып, ят гаиләләрнең беренә киттеләр. Ислам гаиләсеннән, милләтнең ханәсеннән гүзәл берничә туташ гаъиб[5] булды.

[1] фөтүхат – яулап алу, басып алу.

[2] фәукыл-гайә – чиктән узган дәрәҗәдә; үтә дә әһәмиятле; ифрат дәрәҗәдә.

[3] тәкмил – тәмамлау; тәмам итеп бетерү.

[4] бәгъзы – кайбер; кайберсе; кайсы.

[5] гаъиб – юкка чыгу; юк булу.

Бу хәл, бер җиһәттән, гаять зур заъигать[1] булса, икенче җиһәттән балаларын мәдәният мәктәпләрендә тәрбия вазифаларыннан ата-аналарны тәмам өркетеп, балаларның мәдәният мәктәпләрендә тәрбия алуларына гаять бөек зур бер комачаудыр.

Милләтнең әдәп хәятендә мондый олы трагедияләр, фаҗигаләр халык назарында милли мәктәпләрнең әһәмиятләрен кат-кат арттырды инде. Ләкин мондый мәнфур[2] фаҗигаләрнең сәбәпләрен һәрвакыт бары тик мәктәп тәрбияләрендә эзләү тугры булмас. Бәлки гаилә хәятендә, гаилә тәрбиясендә, иҗтимагый әхвәлебезнең фәналегендә, иҗтимагый әдәпнең түбән булуында, милли мәктәп юклыгында эзләү һәм күрү дәһа зиядә тугры була алыр.

Әдәби, дини әхвәлебезнең башка җиһәтләренә дә назар итәр исәк, хәл шулайдыр, яхуд дәһа зиядә фәнадер: мәсәлән, революция башланды, гаять куәтле агитация һәрҗирдә таралды. Милләтнең яшь балалары, мөгаллим-мөгаллимәләре ятларның дәгъвәтләренә тәкълид итеп, башка юлларга кереп китеп, халык күзендә мөгаллим-мөгаллимәләр мөттәһәм булдылар; ике арада гаять бөек тәнафер[3] хасыйл булып, халык – мөгаллимнәрдән, мөгаллимәләрдән, мөгаллим-мөгаллимәләр халыктан тәмам бизде. Бу хәлдән халык гаять зур зарар күрде.

Мондый фаҗигаләрнең, әлбәттә, сәбәпләре бар. Сәбәпләрнең һәммәсе түгел исә дә, бәгъзылары, бәлки иң зурлары, әлбәттә, үзебездәдер. Шуңа күрә, мондый фаҗигаләрнең сәбәпләрен мәдәният мәктәпләрендә күрү, мәдәният мәктәбләреннән нәфрәтләнү, әлбәттә, тугры булмас.

Мондый фаҗигаләрдән нәҗат чарасы бар исә, ялңыз гаилә тәрбиясედер.

---

[1] заъигать – әрәм нәрсәләр; юкка чыккан нәрсәләр.

[2] мәнфур – җирәндергеч; нәфрәт уята торган.

[3] тәнафер – үзара каршылык; яратышмау; бер-береңнән җирәнү.

56) Мәктәп китабларын, гыйлеме хәл[1] китапларын, әхлакъ китапларын, тарих мөкатдәс[2] китапларын Диния назарәте белән бәрабәр һәйәт гыйльмия ислях итәр.

Исламият дөньясының әдәби, иҗтимагый, дини хәлләрен ислях тәдбирләре арасында бу тәдбир иң баш тәдбирдер. Байтак сәнәләр дәвамында кирәкле булып калачак бу тәдбир, бу вазифа бүген башланыр.

57) Сәвад, әдәп, һөнәр тәгълиме мәҗҗанән булып, мәҗбүри булыр. Кабилиятләренә күрә, заманның, милләтнең хаҗәтләренә күрә; балаларның һәрберен тәрбия [кыйлу], әлбәттә, фарыздыр.

58) Милләт балаларын тәрбия өчен лязем булачак сәрмая,– исламият хөкеменә күрә,– милләтнең иң әүвәлге, иң мөфид, иң бәрәкәтле вазифасыдыр.

59) Мәктәп-мәдрәсәләргә, мәсҗедләргә, тәрбия йортларына,– гомумән, хәерле максатларның һәрберенә,– әһле исламның һиммәтләреннән һәрҗирдә иганә тупланыр.

60) Дини, милли, әдәби ихтыяҗларның һәрбере милләтнең үзенең сәрмаясе белән тәэмин кыйлыныр.

61) Мәгариф юлларына махсус сәрмаяләрне, махсус хыссаларны[3] милләтнең әфрады[4] өстенә Милләт мәҗлесе яхуд Диния назарәте сала алса да, тәэминатның күпчелеге вакытына кадәр милләтнең һиммәтенә, милләтнең ихтыярына хәвалә[5] кыйлыныр.

62) Милләт ятимнәрен, инкыйлаб фәкыйрьләренең балаларын мәдәният мәктәпләрендә тәрбия итү кебек мөһим хаҗәтләрне идарә итә алачак сәрмая тәшкил итү хакында сугыш байларының һиммәтләренә Өфе нәдвәсе дә, Диния назарәте дә мөрәҗәгать итәр.

---

[1] гыйлеме хәл – ислам дине нигезләре буенча дәреслек.

[2] тарих мөкатдәс – изге тарих (пәйгамбәрләр тарихы, ислам тарихы кебек төшенчәләр).

[3] хысса – өлеш, кисәк; квота.

[4] әфрад – фәрд с-нең күплек саны шәкеле.

[5] хәвалә – бер эшне икенче берәүгә тапшыру, йөкләү; почта аша, яки башка арадашчы аркылы акча күчерү.

63) Милләт сәрмаясе мөтәгаддид мәнбәгъләрдән[1] хасыйл була ала: 1) ислам вакыфлары, 2) мөселманнарның васыятьләре, 3) гошер, зәкят кебек сәдәкалардан, маликләрнең ихтыяры белән ифраз[2] кыйлыначак хыссалар, 4) никях сәгатьләрендә ике тарафтан милләт хәзинәсенә тәкъдим кыйлыначак һәдияләр, гакыд һәдияләре, 5) ислам дәфтәрләренә теркәлү өчен вилядәт һәдияләре, 6) исламда мөәккид[3] сурәттә мәснүн[4] нәсикә[5] һәдияләре.

Бөтен мөселманнарның хөсн-е ризалары[6] белән тәкъдим кыйлыначак мәнбәгъләр һәрвакыт булып торыр. Милләтнең мөһим хаҗәтләрен үтәячәк сәрмая фонды, һәрхәлдә, җиңел юл белән тәшкил кыйлына алыр.

64) Руханиларның, мәхәллә хадимнәренең, имамнарның, мөәззиннәрнең тәэминаты мәхәллә зиммәсендә булып, Диния назарәтнең тәэминаты да бөтен милләт һиммәте белән булыр.

65) Сугыш ятимнәре өчен милләт үзе дә тәрбия йортлары тәэсис итәр.

66) Якыннары, мөраббилары[7] булмаган сугыш ятимнәренең хәлләреннән мәхәллә руханилары һәрҗирдә һәрвакыт хәбәрдар булып; йә хөкүмәтнең, йә милләтнең тәрбия йортларына урынлаштырыр.

67) Ятимнәрнең нәсәбләрен, диннәрен заъиг итмәү өчен, ятимнәрнең нәсәбләре, исемнәре дәфтәрләрдә теркәлеп; нәсәбләре, исемнәре, яшьләре, [яшәгән] тәрбия йортлары Диния назарәтендә игълан кыйлынып, ятимнәр дәфтәренә кайид кыйлыныр.

68) Ислам төрек балаларын милли-дини тәрбиядән мәхрүм итмәү өчен, ятимнәрне тәрбия йортларына мөселман мө-

[1] мәнбәгъ – чыганак, чыккан урын; су башы.
[2] ифраз – бүлеп алу, аерып алу.
[3] мөәккид – катгый, ышанычлы; раслаучы.
[4] мәснүн – гадәт итеп алынган.
[5] нәсикә – адарыну.
[6] хөсн-е риза – ирекле төстә; үз иреге белән; үз ризалыгы белән.
[7] мөрабби – тәрбияче, багучы.

дирләр, мөселман мөраббиләр, мөгаллимләр тәгайен[1] кыйлыныр.

## *Хатын-кызларның хокукларына һәм вазифаларына кагылышлы маддәләр*

145) Илаһи хикмәтнең әмере белән белән хатын-кыз белән ир-атның табигый хәлләре, табигый вазифалары төрле һәм мөтәфавет[2] булып яратылган булсалар да, мәдәни, иҗтимагый, сәяси, дини, әхлакый хокукларның һәрберен хатын-кызларның һәрберенә ислам шәригате тулысы белән, кәмалы белән бүләк итте. Шуңа күрә:

145) Хатын-кызлар һәр хокукта ир-ат белән тигез.

146) Кайбер хосусларда аерма кебек бер хәл бар исә дә, ул аерма хокукта түгел, бәлки хозузда[3], яки иҗтимагый вазгыятьтә аермадыр. Мәсәлән мирас хыссаларындагы аерма хозуз аермасыдыр. Хозуз кешеләрнең әһелиятләренә бәйле түгел, бәлки хаҗәтләренә күрә була. Шуңа күрә, мондый аермаларны хокук аермасына, әһелият аермасына кайтарып кадыру, әлбәттә, хатадыр.

148) Ләкин хокукларга, вазифаларга хатын-кызларның ия булулары мәсьәләсендә иң мөһим нигез буларак, хатын-кызларның хөрмәтләре, гаилә изгелеге, гаилә төзеклелеге, гаилә мәсълихәтләре игътибар кыйлыныр. Шуңа күрә,

149) Гаилә тәртибенә, балаларның сәламәтлекләренә, тәрбияләренә, хатын-кызларның вөҗүдләренә, сыйххәтләренә[4], хөрмәтләренә, гыйсмәтләренә зарар бирә алачак вазифалардан, хезмәтләрдән һәрвакыт һәрҗирдә хатын-кызларның тәмам азат калып; хөрмәтләренә лаек булмаган хокуларыннан да хатын-кыз һәрвакыт югары калыр.

150) Мондый аермалар аларның [хокукта] тигезлекләренә зарар бирмәс, бәлки хөрмәтләрен ныгытыр. Гаиләләрнең

---

[1] тәгайен – билгеләү; ачыклык, билгеле булу.

[2] мөтәфавет – аермалы, үзгә; бер-берсеннән аермалы.

[3] хозуз – өлешләр; язмышлар; бәхетләр, уңышлыклар; рәхәтлекләр.

[4] сыйххәт – дөреслек; сәламәтлек.

рәхәте вә сәгадәте, төзеклелеге хосусларында, балаларның тәрбияләре, әдәпле булулары хосусларында хатын-кызларның гаять зур әһәмиятләре, гаять әһәмиятле вазифалары бар. Фараз итик, бу вазифаларның берсенә йә күпчелегенә сәяси хокукларның берсе мөрәҗәгать итәчәк булса, мәсълихәт мөляхәзасы белән андый сәяси хокуклары тәрек кыйлыныр. Тәрек итү мәхрүмият түгел, хөрмәттер, мәсълихәттер.

151) Һәрхәлдә хокукларның һәрберенә, вазифаларның да һәрберенә, мәсълихәтләрнең дә һәрберенә, ирләрнең һәрбере кебек, хатын-кызларның һәрбере дә әһелдер.

152) Гаять авыр аналык вазифалары, гаять әһәмиятле гаилә идарәсе хатын-кыз хокукларының [гамәлгә ашуына] киртә яки комачау кебек кабул ителмәс.

153) Хатын-кызларның хокуклары никадәр кямил булса, хөрмәтләре ннкадәр зур булса, һәйәт иҗтимагыя дә шулкадәр куәтле булыр.

Әһелияте дә, хокуклары да кямил булган хатын-кызларның ана булулары да, сөелүләре дә зур була, бәрәкәтле була. Хокукларның кайберләреннән хатын-кызларның мәхрүмиятләре, йорт диварлары арасында хатын-кызларның әсирлекләре гаилә җиһәте белән файдалы булмый.

154) Ләкин иҗтимагый вазифаларына, иҗтимагый әһәмиятләренә, әдәби, табигый вазифаларына сәяси-иҗтимагый хокуклары зыян китерерлек булса, андый хокуклардан файдаланулары таләп ителмәс.

155) Гаиләләрнең низамнарына, интизамнарына, балаларның тәрбияләренә зыян китермәү зарурәтенә күрә, ханымнар, кызлар мәҗбүри хезмәтләрнең һәрбереннән, әлбәттә, азат булып; дәүләт йә җәмәгать хезмәтләренең һичберенә ханым вә кызларның һичбере мәҗбүри сурәттә сөрелмәс.

156) Фабрикаларда, заводларда, шахталарда хатын-кызларның хезмәтләрен мәдәният дөньясы да, икътисадчы галимнәр дә кабул итсә, моны кабул итеп кичерсә, мондый хезмәтләргә мәҗбүр итү дәһшәтләреннән, бәлки хатын-кызларның вөҗүдләренә, сәламәтлекләренә, гыйсмәтләренә зарар бирә алачак хезмәтләрнең һәрбереннән үзләренең кызларын, ха-

тыннарын азат итү вазифаларында ислам дөньясы да, Русия мөселманнары да, моннан соң, әлбәттә, иҗтиһад итәр.

157) Бүгенге мәдәниятнең мондый дәһшәтле бозыклыкларыннан котылу чараларын эзләү һәм табу Русия мөселманнарының да, бөтен җир йөзе мөселманнарының да мөһим бер вазифаларыдыр. Шуңа күрә,

158) Нәфәкаләрен үзләре кәсеб итә алырлык кадәр хатыннарыбызны, кызларыбызны тәрбия итү, әлбәттә, зарурдыр. Хатын-кызларның шундый бер вазгыятьтә, шундый бер кодрәттә булулары хокукларының да, хөрриятләренең дә, хөрмәтләренең дә иң куәтле саклаучысыдыр.

Һәйәт иҗтимагыядә ике әйбер: берсе – җаһиллек, берсе – зарурилык кешеләрнең һәрберен, хосусан, хатын-кызларны сәфаләтләрнең һәрберенә сәвыкъ итә.

Кызларны тәрбияләүнең гаять мөһим бу җиһәтенә дә, әлбәттә, игътибар итү гаилә аталарына да, өммәт раһбәрләренә дә бүген, әлбәттә, ляземдер.

159) Ханымнарның, кызларның хокукларына һәм вазифаларына багышланган бер китап фикъһы китаплары арасында юк. Хатын-кызларның табигый халәтләренә кагылышлы фикъһы хөкемнәренә багышланган бәяннар фикъһы китапларында тәһарәт, саләт, гыйддәт кебек китапларда бар исә дә, мөҗтәһидләрне дә сәргярдан[1] итәр кадәр авырдыр. Шуңа күрә, хилафәт исламиянең мәшихәт исламиясе вә ислам мәмләкәтләренең һәйәт фикъһияләре мәгърифәте белән, хатыннарның һәм кызларның хокукларына вә вазифаларына, табигый әхвәлләренең, фикъһый әхвәлләренең хөкемнәренә багышланган һәм мөҗиз, һәм асан, һәм мәзбут[2] бер китаб тәэлиф кыйлынуб, мәктәб-мәдрәсләрдә тәдрис кыйлынур.

---

[1] сәргярдан – баш әйләндерү; баш әйләндергеч.

[2] мәзбут – конфискацияләнгән; нык, какшамас; ныгытылган; теркәлгән, регистрацияләнгән; хәтердә ныгытылган.

# Муса Җаруллаһның Әнвәр-пашага язган хаты[1]

Мөхтәрәм Бөек раһбәр әфәнде хәзрәтләре!

Мин гаять олы шатлык белән шөкер итәм, Төрек раһбәрләренең, аеруча Сезнең хөрмәтегез, тәэсирегез Төркестан мөселманлары хозурында гаять зурдыр. Һәрберегезнең һәр сүзе Хәзрәт-и шаригъның фәрманы кебек кабул ителә. Ышанычлы затлар арадашлыгы белән әледән-әле хәбәр бирә торсагыз, Төркестанда әһәмиятле олы куәт тәшкил итә алырсыз, бары тик раһбәр юклыктан аптырап калган, туктап калган куәтләрне хәрәкәткә китерә алырсыз.

Бакуда үткәрелгән съезд көннәрендә Сезнең хозурыгызда ант итеп сүз биргән ике әфәнде (исемнәре, номерлары бәлки дәфтәрегездә бардыр) малларыннан, җаннарыннан, гаиләләреннән ваз кичеп, тәмам җитдилек белән гаять бәрәкәтле сурәттә акыллы бер сәясәт юлында хәрәкәт итәләр.

5554 номер иясе Шәркый Тараблүс әфәнде Төркистан комитетларының иң иманлы, иң кыю, алдын-артын иң уйлап эшләүче рухыдыр. Төркистан куәтләрен мәркәз белән бәйләп торучы дә Шәркый әфәнде җәнабларыдыр.

5555 номер иясе Бакудан кире кайткан минутында кичектерүсез бер куәт тәшкил итеп, төрледән-төрле һәм күпсанлы курбашиларны берләштерү хосусларында тырышлык күрсәтеп уңышка иреште. Фәрганәдә егермедән артык төрледән-төрле куәт бар иде, бүген өч куәт калды, Ширмәт, Рахманкол, Җаныозак куәтләре. Бу өч милли куәт берләшү юлындалар. Рахманкол, Җаныозак куәтләре дә бәлки якында берләшер, бердәм сурәттә хәрәкәт итәр. Ширмәт, бәлки, кабул итмәс, иттифактан качар. Шәркый Тараблүснең фаразлавына күрә,

[1] Чыганак: Türk Tarih Kurumu Arşivi. EP 6.1.1.2. (Татар теленә тәрҗемә ителде).

[Ширмәтнең болай итүе] Әфганның сәясәте, Әфганның мәкере, котыртуы куәте белән, имеш.

Бөтен Төркистанның азатлыгына сәбәп була алачак милли куәтләр күбәюләре, күтәрелүләре, үсешләре дакыйкасында Мәмдүх Шәүкәтбәк хәзрәтләренең коралны тапшыру турындагы фәрманы Сезнең сәясәтегезгә туры киләме? Акыллы бер тәрбия була алырмы? Төркия инкыйлаби хөкүмәтенең гамәлдәге сәясәте күзлегеннән [бу фәрман] кирәклеме, файдалымы, сәяси бер мәсълихәтнең таләбенә күрәме бирелде?

Яки, Сезгә мәгълүм түгелдер, Сезнең белән Мәмдүх Шәүкәтбәк хәзрәтләренең хәрәкәтләре арасында, бәлки, һичбер бәйләнеш юктыр. Юкса, Сезнең сәясәтегездә дә тулы бер алмашу, тулы бер инкыйлаб булган булса, хәбәр җибәрү, яңа тәгълимат җибәрү, әлбәттә, Сезгә тиешле иде.

Мәмдүх Шәүкәт хәзрәтләре комитетларны да яптыру хакында катгый җитди киңәшләрен Габбас хуҗа җәнапләренә ачыктан-ачык әйткән. Төркия инкыйлаби хөкүмәте фәрманы буларак ирештерелгән бу хәбәр Төркистан комитетларын аптырашта калдырды. Сәмәрканд комитетының әгъзалары арасында бу хакта каршылыклар чыгып, комитет ике төркемгә бүленде. Һәрхәлдә, Төркистан комитетларының [эшләрендә] туктап тору барлыкка килде.

Мәмдүх Шәүкәтбәк хәзрәтләренең хәбәрен я раслау, яки кире кагу юлында күрсәтмәләр ирештереп тору Сезнең тарафтан, әлбәттә, тиешле иде. Мондый бер гамьсезлек, бу кадәр зур игътибарсызлык төрекләрнең тышкы сәясәтләрен тәмам куәтсез итә, тәэсирләрен дә юкка чыгара. Хәйдәрбәк Шәукый хәзрәтләреннән кала тагын бер ышанычлы адәмне, бөтен күрсәтмәләрегезне ирештерүдә арадашчы була алачак вәкилегез буларак, тәгаен итсәгез, Төркистан мөселманнарына юлбашчы булу вазифасы тәэмин ителгән булыр иде, вакытына күрә һәрбер күрсәтмәгез [бирелгән] дакыйкасында ул җиткерелеп торыр иде. Туры сүзле, ышанычлы бер даими вәкилнең Ташкәндтә булуына ихтыяҗларын, теләкләрен комитет әгъзалары миңа сөйләделәр; хатта Сезгә язуымны да миннән таләп иттеләр. Эшнең мәсълихәтенә күрә, мин яздым.

Чыннан да, Төркистан кебек зур бер кыйтга өчен, бары тик бер адәмнең, бары тик Хәйдәрбәк Шәукый хәзрәтләренең аз булуы, әлбәттә, күренеп тора.

Ташкәнд белән Москва арасында даими аралашулар бар, киткәннәр-килгәннәр арасында ышанычлы кешеләрне табу һәрвакыт мөмкиндер. Күрсәтмәләр күндерелеп торса иде, яхшы бер тәртип хасил булып, начар ният белән куллану юллары да ябылыр иде. Төркистан комитетларының хәрәкәтләрендә дә, фәрманнарында да зур-зур хаталар бар, имеш; Фәрганә курбашиларының хәрәкәтләрендә дә яманлык һәм золым күп, имеш. Сезнең авызыгыздан күрсәтмәләр ирештерелсә иде; комитетлар хата хәрәкәтләрдән, курбашилар золымнан, яманлыктан котылыр иде. Минем белән очрашкан сөйләүчеләрнең сөйләгәннәре дөрес булса, һәм рус гаскәре, һәм курбаши гаскәре диһканларның авылларына, шәһәрләренә һөҗүм итеп, угрылык итә, имеш, халыкның малларын, хайваннарын талый, имеш. Алай булса да, халык гомуми сурәттә курбашиларга тарафдар имеш, курбашиларга авышулары артыграк, имеш. Мөҗаһитләрнең гаскәрләре арасында халыкның малларына, хатыннарына, кызларына һөҗүм итү кебек бозыклыкларның юллары киселсә, халык бердәм сурәттә мөҗаһитләргә, курбашиларга тарафдар булып; Төркистанның милли куәте, әлбәттә, җиңү казаныр иде; халыкның маллары, җаннары ике дошманның залимнәрчә бозыклыкларына файдасыз корбан булмас иде.

Өч-дүрт еллык инкыйлаб вакыйгаларында, революция фетнәләрендә Фәрганә диһканнары гаҗәеп бер ныклык, сокландыргыч бер чыдамлык күрсәттеләр: ике дошманның даими һөҗүмнәренә һәрвакыт һәдәф[1] булып; ике дошман гаскәрнең хаҗәтләренә тиешле булган һәр төрле ризыкны да тауган вә кәрһан[2] әзерләп; корылык елларының тәкатьтән ашкан авырлыкларына да батырларча каршы торып; дин һәм ватан азатлыгы юлында Сезнең ишарәләрегезне бөтен иманнары

[1] Һәдәф – төбәп ату ноктасы; мишень.

[2] Тауган вә кәрһан – ирекле һәм ирексез рәвештә.

белән, куәтле өметләре белән көтеп торалар! Сокландыргыч ныклык.

Фронтларның һәрберендә Совет дошманнарының һәрберсе җиңелде; бары тик һич бер җирдән ярдәм алмаган, раһбәрләре булмаган Фәрганә пролетариясе мөдәфәга юлында ныклык күрсәтеп, куәтләрен, интизамнарын һаман да арттырып, ныгыды.

Ышанычлы бер кешедән хәбәр алдык: Фәрганә мохтариятен игълан итү хакында Төрек бюросына, ТурЦК әгъзаларына Сталин җәнапләреннән фәрман килгән. Бу хәбәрнең дөреслеген яки ялган булуын ачыклау Сезнең көчегездән килә. Сезгә ул бәлки моннан алда ук мәгълүм булгандыр. Фәрганә курбашиларын Совет тарафына җәлеп итү хосусларында Төркистан хөкүмәте сәяси чаралар кулланачак, имеш; уңышлы булмаса исә, Унынчы съезд карары белән Фәрганә мохтарияте Төркистан хөкүмәте тарафыннан игълан ителәчәк, имеш.

Мондый «имеш»ләр тугры булса да, булмаса да, Фәрганә мөҗаһитләре Төркистан мөстәкыйльлек казанганга кадәр сугыша алырлар, сугышачаклар. Русиядә эчке вазгыять, икътисади кыенлыклар, тышкы сәяси әхвәлләр бәрәкәтле бер җирлек, форсатлы ганимәтләр бер заман әзер итде. Фәрганә курбашиларының көтелмәгән уңышларга ирешүләре дә якын ихтималдыр.

Болай булгач, комитетларның хәрәкәтләрен туктатып, Фәрганә курбашиларының коралларын тапшыруның кирәге бармы? Мәсълихәте бармы? Һәрхәлдә, Сезгә гаять ашыгыч рәвештә күрсәтмәләрегезне бәян итәргә кирәк.

Ризалыгыгызны бәян итеп, я Мәмдүх Шәүкәтбәк хәзрәтләренең киңәшләрен хупларсыз да Төркистан мөселманнарын аптыраштан, икеләнүләрдән коткарырсыз; яки әүвәлге фикерләрегезне алга сөреп, бүген кирәк булган күрсәтмәләрне дә бәян итеп, Мәмдүх Шәүкәтбәкнең киңәшләре урынына үзегезнең киңәшләрегезне бәян итәрсез. Бу очракта, Сезнең белән Мәмдүх Шәүкәтбәкнең фикерләре арасында каршылыкның сәбәпләрен дә бәян итү кирәк булачак. Сәяси хәрәкәттә Сезнең элеккеге дусларыгыздан булган Мәмдүх

Шәүкәтбәк хәзрәтләре бүген Төркия инкыйлаби хөкүмәтенең вәкиле исә, тышкы сәясәттә Сезнең белән Мәмдүх Шәүкәтбәк хәзрәтләре арасында һичбер каршылыкның булмавы тиеш иде. Юкса, Төркия инкыйлаби хөкүмәтенең тәэсир көченә дә, Сезнең тәэсир көчегезгә дә зур зыян, бәлки, килер. Суйсаллы Исмәгыйл Собхи хәзрәтләренең кайбер бәяннарында да каршылык барлыгын бераз аңладым, күңелем төште. Аларны сиздермәүләре хакында үтендем, сорадым. Әлбәттә, ул минем үтенечемне кабул итде һәм Конференциядә Сезне дә инкыйлаби хөкүмәтнең раһбәрләре кебек күрсәтте.

Совет хөкүмәте, бәлки Ленин җәнапләренең үзе Шәрык сәясәтендә шәрыклыларның үзләренә таянмый. Ул, хәтта, шәрыклыларның коммунистик тәшкилатына да ышанмый. Татар-башкорт гаскәренә дә таянулары юк. Төркистан җирләреннән ир-ат гаскәргә алынмый; алынган очракта да, кулларына корал бирми, хәрби булмаган хезмәтләрдә генә кулланa. Күпчелеге мөселман булмаган гаскәрне Төркистанда тоту өчен хөкүмәт кулында бер сылтау булырга тиеш, имеш. Фәрганәдә гыйсъян хәрәкәтләре исә шуның өчен яхшы бер сылтау, имеш. Шуңа күрә, Фәрганә хәрәкәтләренең дәвамы Төркистанда Совет сәясәте өчен таләп ителә, имеш. Хөкүмәт кулында мондый сылтауларны калдырмас өчен, Фәрганә курбашиларының бүгенге хәрәкәтләрен бер вакыт алдан бетерергә кирәк, имеш.

Бу да – бер фикер йөртү рәвеше. Мондый фикер йөртү рәвешен асраган башлар Төркистанда да бар. Мәмдүх Шәүкәтбәк хәзрәтләренең киңәшләренә дә шундый бер фикер йөртү рәвеше, бәлки, нигез була алыр.

Минем карашымда шундый фикер йөртү рәвеше тугры булмаса кирәк; бәлки, әлбәттә, тугры түгелдер, ачык хатадыр. Рус хөкүмәте кулына бер сылтау кирәк исә, андый сылтаулар, бәлки тагын да зурлары, һәрвакыт табылыр. Төркистан мөселманнарына дүрт-биш хәрби раһбәр күндерү кебек юк кына бер ярдәм итүгә бүген Төркия инкыйлаби хөкүмәтенең көче юк исә, кырык-илле мең коралланган милли куәтне Совет кулына тапшыртып, Фәрганә курбашиларының һәм дә га-

иләләренең каннарын, җаннарын тәмам әрәм иттерү, Фәргано кебек бәрәкәтле бер вилаятьне корбан итү кебек нәтиҗәләргә сәбәп була алачак киңәшләр бирүнең кирәге дә юк, хаҗәте дә юк, файдасы да юк. Төркистан мөселманнарын, кимендә, үз ихтыярларына калдыру мөмкиндер.

Фәргано хәрәкәтләренә Совет хөкүмәте күзе белән багып, Фәргано курбашиларына угрылык, басмачылык, золымчылык кебек һәртөрле яманлыкларны кыйлучы итеп күрсәтеп, аларга яла ягу уйлары да Мәмдүх Шәүкәтбәк хәзрәтләренең фикерләренә, киңәшләренә нигез була ала.

Бу кадәр олы яла Советтан чыккан яладыр, ул дөреслеккә туры килми. Фәргано курбашилары, Фәргано гаскәре, диннәрен, намусларын, хөрриятләрен, хокукларын, җирләрен химая итүче мөҗаһитләрдер, ватан пролетарияседер. Караңгылык, наданлык тарафдарлары булган ишаннар, мал колына әйләнгән буржуйлар Фәргано мөҗаһитләре арасында юк. Бүген Русия кебек һәм халкы, һәм гаскәре ач булган зур бер дәүләтнең күршесе булып калган Төркистанда азмы-күпме бәрәкәтнең, ризыкның булып торуы, саклануы – ягъни төркистанлыларның тәмам ачлыктан, юклыктан котылулары Фәргано курбашилары аркасында гына димәк мөмкин. Юкса, Төркистанда һичбер бәрәкәт калмас иде; ач гаскәр, ач халык Төркистан мәхсуләтләрене[1] тәмамы белән йотар иде. Фәргано кораллары ач гаскәрнең кулына тапшырылса, Фәрганәдә ачлыктан интегүчеләргә Анадолу бәрәкәтләрен Мәмдүх Шәүкәтбәк бүләк итә аламы?

Фәргано мөҗаһитләренең таләпләрен кабул иттереп, хокукларын тәслим иттерү юлында Мәмдүх Шәүкәтбәк хәзрәтләре үзенең кайбер тәүсыяләрен Совет хөкүмәтенә ирештерә алсалар, тагын да яхшырак булыр иде. Ихтыяр хокуклары, идарә хокуклары, милек һәм җир хокуклары, дин хокуклары, истикляль хокуклары бирелгән булса иде, Фәргано мөҗаһитләре җиһадка күтәрелмәсләр иде. Фәргано мөҗаһитләре дашнак бандалары түгел; угры түгел. Бәлки үзләренең инсани хокукларын, ватани хокукларын, дини хо-

[1] Мәхсуләт – уңыш, керем; продукция.

кукларын, милли хокукларын яклаучы бөек бер куәттер. Шәрыкътә Төркия сәясәтенә, (әгәр дә бүген Төркия инкыйлаби хөкүмәтендә Шәрыкъ сәясәте бар исә) яки якында Төркистанның азат ителүенә сәбәп һәм хадим булачак гаять әһәмиятле бер куәтдер. Әнвәр бәкләрнең хәрби даһилыклары Фәрганә җирләрендә гаять зур җимешләр бирә алып, бөек инкыйлабларның юлларын ачар иде. Анадолу мәйданнарына тәэсир итә алмаган әнвәрләрнең җире бүген Москва түгел, Фәрганәдер. Совет капуларында гидайлык хәрәкәтләре белән канәгатьләнү әнвәрләрнең җегәрләренә бүген туры килми; бәлки Шәрыкъ төрекләренең куәте белән ислам җирләрен азат итеп, Совет шигарьләрен исламият юлы белән, ислами гамәлләр белән чыгарып, Совет хөкүмәтенә ярдәм итү әнвәрләрнең җегәрләренә, һиммәтләренә күбрәк мөнасыйптыр.

Акыллы бер сәясәт Фәрганә куәтләрен Совет һәм Төркия мәсълихәтләренә туры килгән сурәттә хезмәт иттермәсә, һәм Советка, һәм Төркиягә зарар китерү өчен, Фәрганә куәтләрен инглиз сәясәте үзенә хезмәт иттерәчәк. Мин, зинданда мәхбүс булган көннәрдә, мәхбүсләрнең берсеннән ишеттем: Совет Антанта белән килешү корганга кадәр, дамелла Садреддин япунларга мөрәҗәгать итте. Совет хөкүмәте Антанта хөкүмәтләре белән килешү төзеп, Шәрык хәрәкәтләре бөтенләй туктаганнан соң, Фәрганә мөҗаһитләре, әлбәттә, инглиз хөкүмәтенә мөрәҗәгать итәр. Инглиз хөкүмәте Фәрганә мохтариятен дә өч ел элек мөкаддәм рәсми төстә таныган иде.

Хат язу тәкате Сездә бәлки юктыр. Ләкин матбугат булмаган бер заманда җәридәләрдән дә озын хатларны укымак тәкате яки теләге бәлки бардыр. Шуңа күрә, һәм дә мәсьәләләрнең әһәмиятләренә күрә, бу хатымны яздым. Миңа мәгълүм булмаган бәгъзы мәсьәләләрне Сезгә күрсәтим. Хәйдәрбәк Шәукый хәзрәтләре арадашлыгы белән җавапларын бәлки бәян итәрсез.

1) Совет хөкүмәте белән Инглиз хөкүмәте арасында «Сәүдә килешүе» имзаланганнан соң, Шәрыктә инкыйлаби хәрәкәт ихтималлары калдымы? Яки калыктымы?

2) Шәрыктә инкыйлаби хәрәкәт юллары Совет хөкүмәтенә нисбәтән «Сәүдә килешүе» куәте белән ябылган булса, ислам мәмләкәтләре бүгенге әсирлекләрендәме калачак?

3) Сезнең белән Төркия инкыйлаби хөкүмәте арасында мөнәсәбәт нинди?

4) Төрекләрнең, хосусан, Сезнең ислам дөньясында тәэсирегездән файдалану чаралары тулысынча сызып атылачакмы?

5) Совет хөкүмәте белән Сезнең мөнәсәбәтегез нинди? Бәрлин урамнарында Тәлгать Паша хәзрәтләренә тәгадди итмеш[1] хыянәт куллары Москва сарайларында Сезгә дә тәгадди итмәсме? (والله يعصمك من الناس)[2]

Безнең белән бергә мәхбүсләрдән төрмәдә сигез кеше калды. Габидулла хуҗа кардәше идарәләрнең берсендә хезмәт кыйлынмак шарты белән якында бәлки чыгар. Рөстәмбәк исемле бере, элек полициядә эшләве гөнаһына күрә, бәлки сөргенлеккә җибәрелер, Төркестандан чыгарылыр. Комитет эшләрендә Кари Мөнәввәрнең гөнаһы юк; басмачылар белән мөнәсәбәте дә, шаһитның ялганлыгы исбат ителеп, исәпкә алынмаячак; моңа күрә Кари Мөнәввәрнең якын көннәрдә нәҗаты да ихтималдыр. Гаять мәгълүматлы, иманлы, әһлиятле яхшы егет Гариф әфәнде Кәрими хәзрәтләре хат ташучы булуы гөнаһы белән үлем җәзасына хөкем ителә ала. Балкан сугышлары көннәрендә үз теләге белән Төркия сафларына да барган иде. Һәр хосуста файдаланыла алачак, һәм дә иң бөек хосусларда да файда китерә алачак яшь каһармандыр. Русча югары тәрбиясе бар. Сезгә яки Сталин кебек хөкүмәт раһбәрләренә, яки Төркия инкыйлаби хөкүмәтенә әһәмиятле хөзмәтләрне җиренә җиткереп башкара ала торган ышанычлы, кыю, фидакяр егетләрдер. Азат иттерү хакында никадәр җитдилек белән тырышсагыз да, урынлыдыр. Мәхбүсләр арасында Сезнең тарафдарыгыз дамелла Шами хәзрәтләре дә бардыр. Асыл исеме Мөхәммәд Сәгыйт әл-Гаслидер. Кәшгар һәм Чин вилаятләрендә унтугыз ел кадәр яшәгән һәм

[1] Тәгадди итмеш – үтерү нияте белән һөҗүм иткән.

[2] Вә Аллаһу йугсымукә минән-нас – Аллаһ сине кешеләрнең яманлыгыннан сакласын.

сәяхәт иткән. Голүм исламия, голүм әдәбиясе зәгыйфь исә дә, гарәпчә шигырь сөйләмәк-язмак кодрәте бар. Табигате нәфис, кәефенә күрә кызып китүчән бер пир исә дә, гаять яхшы җиһәтләре дә бар. Мондый бер адәмнең яхшы җиһәтләреннән файдалана алмыйча, хокукларын, хөрмәтләрен тулысынча санга сукмау төрекләрнең зур бер җитешсезлекләредер. Дамелла Шами хәзрәтләренең Хәйдәрбәк Шәукый, Сәлим Сами, Хәлил Паша хәзрәтләренә мәгълүм булган тискәре сыйфатлары да, бәлки, бардыр; дамелла Шами хәзрәтләренең миңа карата да зур дошманлыгы, бәлки, бардыр. Ләкин, һәрхәлдә, даммела Шами хәзрәтләренең гаять гүзәл җиһәтләре дә, башкаларда очрамый торган игелеклекләре дә бар. Илле көнлек мәхбүсият мөгамәләләрендә мин гаять ачык күрдем: төрекләрнең тышкы сәясәте дә, хәтта төрекләрнең әдәбияты дә бу пирнең яхшы хезмәтләреннән гаять нәтиҗәле сурәттә файдалана ала иде. Сез азат иттерегез, мин ул кешегә хезмәт күрсәтим.

Бу хат язылган кәгазьләр кулымда ике атна кадәр мәхбүс хәлендә калды. Хатеремә бер нәрсә килгән саен, аны язып куя идем. Җөмләләремдә, әлбәттә, тәртип юк.

Мәмдүх Шәүкәтбәк хәзрәтләренең киңәшләре хакында Сезнең кичектергесез ашыгыч чаралар күрүегез кирәк. Юкса, бөек куәт файдасыз харап булачак.

Сезгә соңгы үтенечемне белдерим: илле көн төрмәдә яттым; кырык көндер инде шәһәрдә мәхбүсмен. Гөнаһым юк; хезмәтем бар; файдалана алсагыз, Сезгә һәм дә Төркия инкыйлаби хөкүмәтенә, бәлки Шәрык инкыйлабына зур әһәмиятем була алыр; Сезгә беркадәр бәйләнешем дә бардыр; һәм Сезнең һәм Җәмалның йөкләмәләрендә беркадәр хокукым да бардыр. Минем ихтирам белән азат ителүем мәсьәләсендә гаять ашыгыч буларак Сезнең хәрәкәтләрегез, тырышлыгыгыз кирәктер. Ун җанлык гаиләм бар; үзем унберенчесемен. Миннән башка хезмәт күрсәтүчеләре юк.

Мине азат итү хакында катгый тырышлык күрсәтүегезне үтенәм. «Исламият әлифбасы» исемле бер китап яздым. Дүрт-биш җирдә басылып, шанлы төрек гаскәре шәрәфенә,

инша Аллаһ, нәшер ителер. Төркия инкыйлаби хөкүмәтенең тышкы сәясәтенә, инша Аллаһ, хезмәт итәр. Июль ахырына кадәр Москвада яки Русиядә торсагыз, әһлиятле каһарман бәрадәрләр белән бергә Сезне зиярәт итәр идек; Сезгә мөһим мәгълүмат бирүб, Сездән тәгълимат алыр идек.

Русия җиренә аяк басканнан соң Төркия җирләренә әйләнеп кайтмавыгыз мине һәм дә кайбер бәрадәрләрне төрле шөбһәләргә авыштырды. Фараз итик, Төркиядә Сезгә урын юк исә, Шәрыктә Сезгә гаять ихтирамлы урын хазирдер. Сезнең киләчәгегезнең кояшы Шәрыктә күтәрелер. Ислам кылычын уң кулыгызга алып, йөрәгемдәге Коръән кәрим белән миемдәге ислам шәригатенең куәте белән мин дә Сезгә рафыйк булыйм.

Шәрык сарайларында Сезнең өчен риясәт көрсиләре әзердер.

Фәрганәдән килүче кардәшләрнең риваятьләренә күрә, бүген кумандалык итүче өч курбашидан (Түрәкол Җаныузак, Рахманкол, Ширмәт) Ширмәтнең алмашына мелла Габдерраззак исемле яхшы бер зат сайланылган. Мелла Габдерраззак гадел һәм идарә итә белүче бер адәм, имеш. Моннан соң Җаныузак, мелла Габдерраззак, Рахманкол куәтләрен берләштереп, Фәрганә куәтләре олы бер куәт тәшкил итәр. Фәрганәдән Андижан дамеллаларының берсеннән бу сәгать бер [хәбәр] иреште. «Фәрганә быел дәһшәтле корылык эчендә калачак»,– дигән. Җирнең ничә өлеше эшкәртелмичә калган.

Ташкәнд фаҗигасе һәрникадәр тәэсир итеп үзгәреш тудырчак булса да, халыкның өметләренә, иманнарына зарар бирмәде.

Халык һаман әүвәлге теләгендә.

## «Обращение к Великому Турецкому Национальному Собранию»[1]

Посвящаю эту свою книгу «Азбука», написанную мною в честь славной Турецкой Армии, не только в честь пашей и офицеров, но и в честь тех героев, слава которых нигде не упоминается у великих покровителей и защитников Ислама, и в память одного из членов этой славной армии, доверенного руководителя чистой нации, павшего за Ислам – Талаатбека.

Эта моя книга является конспектом вашей великой идеи, ваших элементарных мер о мусульманском мире.

От имени Славной Армии чистой нации, о, ты, доверенный великой нации, Талаатбек, прими мою книгу.

Вам, вашим войскам, их руководителям, пожалуй, всем членам этой великой нации и их женам, дочерям с почтением предложу эту книгу. Примите эту книгу как доктрину и руководство Корана и шариата мудреца – великого Магомета. Вся надежда мусульманского мира направлена к вам, вы тоже, по этим руководствам действуя, создавайте новый мусульманский мир. Славная победа, которую можно посвятить всему миру человечества, будет вашей.

Признавая ваши достоинства, ваше положение, нахожу вашу политику правильной. Я посмотрел результаты этих войн как ваша победа, видел вашими победоносными глазами. Я видел вашу великую, самую значительную силу в вашем убеждении, морали, терпении, героическом руководстве и находил все это в вашей чрезвычайной честности от человеческого бешенства.

Если и дальше эти силы, эти доблести будут сохраняться в ваших чистых сердцах, самая славная победа в будущем обеспечена вам.

[1] Чыганак: РФ ФСБ ҮА. АСД № Р-46032. Документ авторының орфографиясе сакланылды.

По моему мнению то правительство, которое подписалось под губительными пунктами Севрского договора, а также революционное правительство, созданное силой нации, ее убеждением были единой одной идеей и так действовали.

По моему убеждению, все люди, которые ушли с целью расширения сфер действия в Россию и Германию, руководители революции и обновители нового национального государства Турции, почтенный Мустафа Кемаль, являются героями, подданными этой великой идеи.

Это мое убеждение, может быть, в самом деле оно так было. Предположим, что мое убеждение оказалось неправильным, то по влиянию последних событий остается правильным.

В Турции, и, пожалуй, во всем Востоке, внутреннего волнения не существует.

Это восстание является причиной и первым фактором грядущего освобождения Востока, она целиком и полностью служит этому движению.

Конечно, Турция, которая может стать руководительницей таких идей, в особенности в такие времена, не будет входить в разногласие по направлениям в смысле идей и искания карьеры, не допустит она такое преступление от невежества – быть соколом в руках англичан, конечно, самолюбие каждого турка стоит выше.

Мое убеждение и убеждение каждого мусульманина состоит в этом. Это и является первым условием нашего освобождения. Справедливость Ислама, в которой будут отдельные индивидуумы нации в праве, свободе, почтении, в страдании и в благе равны, и заключает в себе наши убеждения.

Революционное Правительство Турции посредством своих представителей, почтенных лидеров Востока: Энвер-Паши, Джал-Паши, Халим-Паши и Селим-Паши, видя проникнутую в наше сердце эту идею в программе большевиков, в самые критические моменты Советской России протянули ей дружественную руку. Более или менее она была использована по

вопросам Азербайджана, Бухары и Туркестана, что обеспечило значительную пользу Советской власти.

Обращение турецких руководителей к Советской власти не является нуждой, а являлось известной поддержкой Советской России, но только у большевиков не было правильной оценки этих фактов обращения почетных представителей всего Востока и правильного использования всего движения на Востоке.

Большевистское Правительство в восточной политике запуталось. По упорству и невежеству большевиков оно впало в ошибку и в результате оказалось прислужником английской политики.

Когда перед ними находится во всех отношениях могущественная держава, такая как Англия, подозрительный взгһляд на движение на Востоке и сомнение в руководителях Турции является ошибкой Ленина.

В 1920 г. Большевистское правительство на Съезда Народного Востока, перед представителями Востока в количестве 2000 человек в своей речи, которая в ложных обещаниях и хитрости дало присягу против капитала и присягу Священной войне, а в 1921 г. 12 марта в Лондоне перед представителями капитала Англии преклонило колени и дало свою преступную подпись. Этим волей-неволей разрушая свою присягу, оно отказалось от своей Восточной политики и действиях.

Этим преступлением правительство большевиков в политике свое оружие сдало англичанам и, таким образом, руководители Коминтерна (как и 11 Интернационала) совершили преступление перед своей великой идеей.

Но от этого Востоку нет никакого вреда. Теперь на Востоке нет нужды ни в каких агитациях и пропагандах большевиков. Восток хорошо понял сущность этих агитаций и пропаганд и хорошо их оценил. Уж не только большевиков, но и всякой другой иностранной державы слова и обещания являются перед глазами Востока ложными. Это вышло так.

Правда, если бы Советское Правительство осталось бы преданным своим обещаниям в восточной политике, то, может

быть, оно принесло бы пользу освобождению Востока и вместе с этим использовать бы и революционное правительство Турции, и разрешился бы поскорее вопрос мировой революции. Я говорю, пожалуй, было так, только пожалуй. Потому что очень ясным является, что существование такого могущественного государства как Турция на Востоке нежелательно и по программе, и по Конституции большевиков, и по идеям интернационала и проч. Советская власть смотрит более враждебно на освобождение Востока от угнетений, чем Англия.

В экономическом отношении Англия победила. В России и в Азии она одна осталась решающей силой. На суше и на море ей нет конкурента. Советское Правительство перестало вести на Востоке агитацию и пропаганду против Англии. Советское Правительство само стало действовать на Востоке как Англия, вести завоевательную политику.

Это – правда, таковою стала действительность. Но вы, носители знамени Ислама, славная армия Революционного Правительства, Национальное Собрание чистой нации, если вы будете действовать с нынешним убеждением, энергией и терпением, то Восток будет вашим. Туркестанские мусульмане, воины Ферганы являются вашей армией. Китайские мусульмане отзовутся на ваш призыв и подчинятся вам. Китайское государство является самым преданным вашим другом, оно тоже стремится к освобождению от ига Запада вообще.

Афганистан – ваш преданный и могучий союзник, Персия нуждается в вашем покровительстве. Индия с ее обильными богатствами и молодежь со своими жизнями к вам стремится. Если вы разумно сумеете руководить силою Востока, то ваши убеждения и ваши меры победят политику Англии.

Если вы сумеете воспользоваться настоящим положением, то эти положения и обстоятельства разрешат Вашу победу.

Народам Востока пустые слова большевиков, их зверства, иго англичан, лишения всего пролетариата и рабство, как и всему человечеству, в полном смысле надоело.

В каждой нации, у каждого индивидуума и у каждой местности стремление к освобождению очень велико.

Освобождение Востока от всякого рода угнетений – в ваших руках, а ваше освобождение зависит от силы Востока. Если вы сумеете руководить, вся Турция и весь Восток будут освобождены.

Германия тоже является вашим другом. Если она раньше была другой точки зрения только ради своей экономической пользы, в настоящее время она будет с вами от принуждения. Другие Европейские Государства то же самое: из-за отвращения к Англии будут или вашими сторонниками, или не будут причинять вам вреда. Самые богатые на земном шаре земли на Востоке с их богатствами в своих неразработанных и разрушенных положениях вполне обеспечивают восточные народы. Пользуясь своими естественными богатствами, Восток временно обеспечен и без посторонней помощи, а постепенно, пользуясь Германской и американской культурой, поднимется.

Для того, чтобы освободиться от постоянного и разрушительного положения культурного мира, для Вас нет нужды обращаться к мерам Карла Маркса.

Вы, Турецко-Революционное Правительство, опираясь на народы Востока, освободите себя, держась политики Ислама и обеспечивая к себе любовь всего мусульманства, поведете мусульманский мир на путь культуры, взяв за основу основной канон Ислама, который обеспечивает право, свободу и честь всего человечества турецкой силой, пером Ислама вы на страницах культурности напишете каноны новой жизни, нового счастья, новой морали земного шара.

Опираясь на помощь Бога, обещание Корана, силу Востока, права человечества, терпение турок, лучами ума будете действовать, троны побед и врата ее для вас сегодня открыты. Если вы сумеете использовать разногласия на земном шаре, готова почва, но не для движения коммунизма, а для освобождения Востока.

Я, как выразитель того, что сохраняется в чертах мусульман, ОПИСЫВАЯ ДОКТРИНУ КОРАНА И ТОЛКУЯ ЕГО, УКАЗЫВАЮ МЕРЫ ОСВОБОЖДЕНИЯ, НАПИСАЛ ВАМ

ЭТУ КНИГУ «Азбука ислама» («Исламият Элифбасы»). По совету делегата Национального Собрания почтенного Исмаила Суйсаллы с целью издать ее отправляю к вам и при этом вручаю эту книгу вам целиком со всеми правами.

Если эта книга будет вами принята и если прочтут ее, то я считаю себя обязанным передать свою любовь и почтение всем вам вообще и в отдельности. Эту книгу я послал также типографиям Кашгара и др.; если она будет распространяться среди далеко находящихся друг от друга мусульман, то я буду считать себя поставщиком самого важного призыва Корана ко всем мусульманам мира в самое нужное время. Для меня это достаточно, как возложенная самим Магометом-пророком миссия.

Чрезвычайные обстоятельства, проявившиеся в дни Революции в России, у многих вызывали изменения их убеждений, но у меня только укрепили мои старые убеждения и взгляды на вещи. Во всякое время, в каждом месте проявляется верность доктрины Ислама.

В моем взгляде на религию культурного человечества в них существовала ужасная извращенность. В мусульманском мире, конечно, также чувствовалась необходимость крупной революции. Предвидя политические революции в мусульманских странах, я очень ясно изложил в упомянутой книге правовые пункты и взгляд на войны, я вложил туда юридические сведения для того, чтобы ими воспользовались мусульманские шариатские юристы. Как ответ на клевету христиан, и как руководство для мусульман, в этой книге я разрешал своим языком вопросы о войне; также отвечал там по вопросам, касающимся убеждений и политического положения мусульман, находящихся в пределах разных государств. И для Революционного Правительства Турции, и для других мусульманских государств я, можно сказать, разрешал вопрос о Халифате и вопрос единения Ислама.

По моему мнению, мусульманские страны больше нуждаются в социальных, религиозных и моральных революциях, чем в политических переворотах. Поэтому я в своей книге

«Азбука ислама» изложил этот вопрос с особым вниманием. Я считаю, что для сглаживания разногласий между суннитами, шиитами, ваххабитами и бабиями нет других мер, кроме указанных в моей книге. Человек, более или менее разбирающийся в этих вопросах, может вполне оценить эти пункты. Если эти пункты будут приняты и проведены в жизнь через мусульманские школы и администрацию, то было бы обеспечено освобождение мусульманских народов от всякого невежества. Тогда мусульманские народы в культурном отношении развивались бы быстрее и скорее и достигли бы своего совершенства. Если эти меры, которые указаны в моей книге, проводились бы в жизнь через Турецкий Духовный назират и через Национальное Собрание, то они сразу дали бы новую жизнь всему мусульманскому миру. Это мое крепкое убеждение и этого ждут от вас все мусульмане.

Старое духовенство, старое Правительство Турции может быть постепенно привели бы всю Турцию и все мусульманство к краху и гибели. Потому что при них, в следствие деятельности христианских наций, мусульманские государства поодиночке стали попадать в руки чужих, Турция теряла свой авторитет, ее области одна за другой, отставая, отделялись от Турции. Большинство мусульман становилось против Турции, больше миллиона мусульманских воинов во время Европейской войны было направлено против Турции. Если бы этого не было, разве тогда друг Ислама Германия была бы так потрясена, разве в настоящее время мусульманский мир смотрел бы так хладнокровно на положение Турции, оставшейся одной среди новых врагов? Эти несчастные события, эта трагедия при первом взгляде кажется наказанием за грехи мусульманских государств, но на самом деле они являются естественными результатами тех положений, которые я изложил в своей книге. Во всяком случае, Турция не может освободиться только собственными силами. Если она в борьбе оставалась в прежнем положении, все равно она не могла бы сохранить свой политический вес и пала бы, наконец, как другие мусульманские государства, под иго других

христианских государств. От этого и для самой Турции, и для мусульманского мира никакой пользы не было бы.

Без сомнения, настоящее Революционное Правительство Турции и Духовный назират уже не будут действовать подобно старым, и они, наверное, воскресят Ислам, привяжут к себе сердца мусульман через Коран. Разумно руководствуясь этими мерами и путями они, наверное, создадут могущественный мир Ислама. Если Турция усвоит такое направление, только тогда она достигнет благоденствия после шестивековых страданий, только тогда она, т.е. Турция, будет оценена перед остальным миром Ислама. Те мероприятия, которые я приводил в своей книге, являются только мероприятиями Ислама, только они могут создать вечное счастье человечества, обеспечить право, свободу и честь всех национальностей, объединят все человечество и уничтожат антагонизм среди народностей всего мира.

Я знаю: перед Европейской войной и во время войны в Турции, Туркестане и др. странах кипели национальные чувства с целью возбуждать в сердцах молодых людей чувства пантюркизма, в этом духе писались романы и это вмешивали в Ислам, все это было чуждо доктринам Ислама, все было мифом. Точно также объединение пролетариата на основе вражды к капиталу будет рождать только эволюцию, но ни в коем случае – исправление человечества. Эта основа никогда не исправит социального положения пролетариата. Я ни в коем случае не допускаю таких искусственных мер (нужду в них) у нас в национальной политике. Я признаю, что национальные чувства как явление Божественное. Небесное вольется в сердца наций через посредства божественных книг. Оно подарено природой, религией, как средство, толкающее (в смысле конкуренции) по пути культуры. Итак, национальное чувство является естественной силой народов.

У отдельных индивидуумов нации и вообще в ней существуют особые способности, отдельные совершенства. Эти способности воспитываются, растут и совершенствуются только при наличии конкуренции. А если так, то национальное чувство является не только необходимым, но желательным.

Та степень национального чувства, при которой совершается наступление на права других национальностей и разгорается антагонизм между нациями, совсем нежелательна и не нужна. От возбуждения национального чувства в такой степени в смысле для него нет никакой пользы. Между тем, такая степень национальных чувств возбуждалась искусственным путем. В этом и заключается вся ошибка, негодность старой культуры, старой литературы, старой политики мира. Это явление есть великое преступление в человеческом мире. Эту форму национального чувства ислам отрицает, но Ислам не против первой естественной степени национального чувства, последнему Ислам не противоречит. Значит, в этом и заключается политика Ислама по национальному вопросу.

Старое правительство этих сторон доктрины Ислама не поняло, поэтому на таких благородных богатых землях природы, как Турция, самые благородные нации, как арабы и турки превратились в самые бедные, в самые невежественные народности и все мусульманские государства подпали под чужую власть, но новое Революционное Правительство Турции, пожалуй, поймет эти стороны политики Ислама. Оно, наверное, воскресит турецкую культуру, наверное, Тюркская нация достигнет высшей идеи, как англичане, но только в другой форме, с другой моралью, подходящей к инструкциям Ислама. Воскреснет культура Ислама и будут мусульманские государства в связи между собою и освободятся от ига других. Этого желает весь мусульманский, вернее говоря, весь человеческий мир.

Политика Интернационала в настоящем смысле и форме ошибочнее, чем любая из прежних политик, она более губительна, чем все. Классовые гражданские восстания и вражда разрушают всю настоящую человеческую культуру, уничтожают всякое стремление, развивают у индивидуумов только стремление к личным интересам, ничего не исправляют в человеческом обществе и не смогут дать никакого блага для мирового пролетариата.

Те доктрины, которые я изложил в своей «Азбуке Ислама», в рациональном смысле являются самой лучшей интернациональной политикой. Прежде всего, права и честь в отдельности и, в целом, человечества, их политическое и социальное значение являются первой целью. Когда угнетают человека или целую нацию лишают самостоятельности и т.д., то по доктринам Ислама разрешается вооруженное восстание против этого, но воевать можно только и только в этом случае; в противном случае жизнь, имущество каждого отдельного человека должны сохраняться.

Если вы будете действовать так же, как действуете сейчас, может быть ваша самостоятельность останется целой и весь Восток добьется самостоятельно свободной жизни.

Достичь политической самостоятельности сравнительно легко, ее можно достичь путем революции, другими политическими способами, договорами, но экономической самостоятельности достичь весьма трудно, для ее достижения требуется долгое время, громадные труды, крупная народная промышленность и справедливое правительство. Существуют ли эти факторы на Востоке? В настоящее время, конечно, их нет. На появление этих факторов в ближайшее время надежды мало. В настоящее время восточные народы «жаждут на берегах Океана», как сказал один из древнейших поэтов Востока.

Самая благородная часть Востока – Турция, Туркестан до настоящего времени остаются пустыми и неиспользованными,– блага этих частей сейчас еще находятся в недрах природы. Дехкане Востока в настоящее время все еще производят самыми примитивными способами, но и этими продуктами пользуются очень мало, большая часть этих продуктов уходит в чужие руки. Эти продукты из рук дехканов уходят в руки разных элементов, а от них в руки капиталистов чужих стран; сами дехкане все время остаются голодными и убогими, волей-неволей в конце концов идут к упадку. Если в таких фразах я смог уже обрисовать вообще экономическое положение Востока, то оно действительно заключается в этом. Конечно,

для этого имеются исторические факторы, социальные причины и т.д.

Вследствие революции в Турции и повсеместно народы земного шара возбудились, воскресли. С этого момента, пожалуй, все меры будут приняты для поднятия этих народов не только правительствами, но и самими народами. Правда, на Востоке нет промышленности и техники, однако на Востоке имеется благородная почва, этих благ народ сам, своим способом, достигнет. Поэтому с тех пор экономические меры государства можно считать более обеспеченными. Такие меры (экономические) являются самыми первыми, самыми возможными и самыми полезными мерами.

Земля целиком принадлежит государству, продукты дехканам, определяемые шариатом налоги, издаваемые с согласия самого народа, разные налоги будут собираться всеми организациями, которые избираются самим народом, и будут сдаваться в казну. В таком случае никакие плодородные земли не останутся пустыми. Тогда пахотой или другими путями народ будет целиком использовать землю.

Мусульманский мир пока везде удовлетворяется своей промышленностью, он может воздержаться от всякой лишней траты, а в нужные дни оказать материальную помощь государству, обществу. Ни один человек не будет прятать своего лишнего имущества, не будут они хранить свои излишки в западных банках, а будут сдавать в свои народные банки, в руки своего народного государства. Другие немусульманские народы значение этого уже очень хорошо понимают, может быть, с тех пор мусульмане тоже будут это понимать.

Эта мера не есть выход из Ислама, эту меру, смотря по времени, можно даже узаконить и сделать обязательной. Тогда, во-первых, не останутся пустые земли, будут выжиматься все блага, народ станет настоящим хозяином, во-вторых, относительно имущественных прав упорядочится абсолютная обеспеченность. Эта абсолютная обеспеченность является самым основным законом общественной жизни. В-третьих, на остающийся в руках народа и государств излишек приоб-

ретутся орудия сельского хозяйства, промышленности, всякие роскоши,– уровень жизни мусульман станет выше. Четвертое: мусульманские дети будут воспитываться в высших учебных заведениях, все лишнее будет расходоваться на дело народного образования. Пятое: таким образом, в течение 15–20 лет будет накапливаться внутренний капитал государства, созреют специалисты по всем отраслям науки, потом очередь подойдет к тяжелой индустрии и проч., все будет, в конце концов, достигнуто средствами самой нации постепенно. Только этим путем восточные государства могут освободиться из-под американского, западного капитала.

Я убежден, что оставшаяся одна среди множества врагов во время Великой Мировой войны нация и ее национальное собрание мои меры (может) считать ничтожными, может быть, перед Национальным Собранием имеются более приемлемые, более рациональные меры, конечно, национальные собрания ничего не упустят из виду. Однако в моем изложении одна сторона имеет значение. Это то, что во что бы то ни стало не передавать государства в руки банков ведущих держав. Такое порабощение ни в коем случае недопустимо.

К сожалению, это явление во всех мусульманских государствах распространено. Поэтому-то этот способ шариатом был запрещен. На Востоке наперекор шариату еще издавна существует внутреннее ростовщичество. Такие явления оставили дехканов Востока рабами других.

Чем так эксплуатировать, угнетать дехканство, тогда уж лучше первобытный строй, в котором не имеется такой эксплуатации.

Предположим, что Америка устроила на территории Турции железные дороги, ископала природные богатства, нанимая за ничтожную зарплату турецких рабочих, и все продукты увезла к себе, ничего не оставляя для турок. Тогда не будут ли эти желдороги содействовать падению родины и народа в целом? Я думаю, человечество, если не осмелится проклясть такую культуру, в крайнем случае (будет) смотреть на нее с отвращением.

В Индии англичанами устроено все, а все-таки туземцы умирают от нищеты: это явление нам ясно указывает отношение чужой культуры и чужого капитала к туземцам. То, что говорится языком великого ученого, великого гения Карла Маркса о капитале, именно относительно ввозного капитала и чужих рук все время остается правильным, вся его критика верна. Поэтому все восточные народы прежде всего должны стремиться к освобождению от влияния чужого капитала.

Еще один вопрос, который я до сих пор еще не разрешил, может быть Национальное Собрание давно уже предвидело и решит этот вопрос. Этот вопрос таков: может ли нация, занимающаяся только войной (воинством), бросающая экономику на сторону, экономически освободиться от ига чужого капитала? По-моему, с первого взгляда ответ прост и ясен. Турки занимались только военщиной и не занимались экономикой страны, поэтому оказались, в конце концов, только политически самостоятельными, но экономически – рабами. Германия и Англия занимались экономикой и у них положение совсем другое. Но опять-таки, положение Англии и Германии несоблазнительное, у них политическое и социальное место в ряду общественных канонов человеческого общества не является естественным. У них все могущество искусственно. Оно накопилось из пота других порабощенных народностей. Такое могущество может существовать временно и мы видим, что уже в Германии и в Англии разными революционными движениями это могущество подрывается. Быть могущественным в таком виде (такого сорта) весьма и весьма нежелательно. Будущая Турция не должна пойти по такому пути.

Правда, человеческий мир прогрессирует (культивируется), совершенствуется, но этот мир совершенствуется и в своей психологии, в своей силе, которая в нем внедряется. Жадность же, вражда и фанатизма тоже совершенствуются. Потребности и аппетиты растут вместе с человечеством. Жадность предводительства, карьеры и деспотизма у человека сильнее остальных чувств. Если относительно имущества

можно договориться (сделать пополам) и поделиться с другими, то относительно предводительства и карьеры человек ни в коем случае не потерпит участия других. Человек может пожертвовать всем своим имуществом, но никак не своей свободой.

Стремление к предводительству и конкуренции заложено в природу человечества и вместе с человечеством оно совершенствуется. В этом смысле и будут развиваться (продолжаться) государства. В этом отношении рассуждения коммунизма неправильны. Поэтому-то и должно создаться мусульманское государство, поскольку существуют сами мусульмане. Эту роль будет играть Турция, следовательно, силы этого государства в последнем смысле искусства.

Так, мусульманское государство создается на двух основах: 1) на основе вечной общей обеспеченности каждого индивидуума в личной жизни и в имуществе, 2) на основе силы, при которой справедливо будут сохраняться обеспеченность и все права народностей.

Доктрины Ислама не принадлежат ни к какой политической партии и ни к какому военному союзу. Ислам не сторонник войн, он должен принять все меры, при которых уменьшаются факторы войны.

На началах, согласно доктрины Ислама, можно создать войско и содержать его и это нужно уже разрешить. Согласно Корана и Магомета, крепко убежденное Революционное Турецкое правительство, конечно, не окажется в недоумении в разрешении этого вопроса. Призывам Корана мусульманство ответит вполне, обсуждая этот вопрос на общем мусульманском съезде и вынесет свое постановление. По инструкции Ислама военная обязанность является самой доблестной обязанностью. Набор в войсковые части, смотря по времени, может производиться или путем жеребьевки, или во всеобщем порядке. Войска будут служить как сила для обеспечения спокойствия жизни всех народностей и больше ничего. Поэтому государство, прежде всего должно обратить свое внимание на воспитание народа в политическом, моральном

и экономическом смысле. Восточные народы смогут освободиться от чужого экономического ига и своей порабощенности тогда, когда будет воспитано молодое поколение, поднято хозяйство своими средствами, своими спецами и своей культурой. Принимать от других культуру и при этом сохранять свое преимущество, с точки зрения совершенства всего человечества, является самой правильной политикой, ассимилироваться очень плохая штука. Наверное, Революционное Турецкое Правительство это хорошо понимает и направит свой народ к такой точке. До сих пор мусульмане, большею частью получая образование, ассимилировались и исчезали из народа. В Турции есть очень много чистых немцев и турко-французов, но образованных чистых турок весьма мало, а в других странах совсем не имеется. С этих пор вам и всем мусульманским государствам нужна благородная, чистая от всех развращенностей, фанатизма и невежества культура. Эту сторону управления государства вы должны иметь в виду.

В последнее время во имя европейского капитала в лице Англии и во имя революции, колонизация стала сильнее, чем была раньше. Пожалуй, с этих дней Революционное Правительство Турции не останется хладнокровным зрителем таких явлений.

Вы нужны мусульманам и, наоборот, от имени всех эту книгу предложу; вы ее примите. Они все выразят усердную преданность за это, везде говорит молчаливое невежественное положение. Это есть молчаливая жалоба, ее даже пером выразить невозможно. Все мусульмане, все туранские тюрки по своему положению как будто бы жалуются на свое невежественное во всех отношениях положение.

Кроме того, я перевел на тюркский язык Коран, если примите, то его тоже желательно издать в честь Национального Собрания Турции. Еще одна книга написана мною о семейных отношениях (положениях), ее тоже предложу вам.

*Помощь Аллаха близка.*
*Муса Джаруллах 1340 года (по-мусульмански).*

# Китап бисмилласы[1]

Унтугызынчы гасыр урталарында бәдбин[2] Карл Маркс кебек матдиятче[3] икътисадчыларның күзлек артындагы күзләре белән күренеп, Көнбатышта иске мәдәният дөньясының зур мәркәзләрендә хәрәкәткә килгән фетнә хыялларының сәяси, иҗтимагый, икътисади сәбәбләре егерменче гасыр башларында җир йөзендә бөтен куәте белән дәвам итеп; хәтта зур фетнәләрнең галәмәтләре буларак, Нәхес әкбар[4] Сатурн белән Нәхес әкбар Марсның, ягъни Зөхәл йолдызы белән Мариж йолдызының күк йөзендә очрашулары да 1912 елда вакыйг булып[5]; диянәт[6] дөньясы белән мәдәният дөньясының соң дәрәҗәдә бозыклыкларының котылгысыз бер нәтиҗәсе буларак, дәһшәтле вакыйгаларның, гаять зур инкыйлабларның[7] барлыкка киләчәкләре турында хәбәр бирәләр иде.

Ләкин мәдәният дөньясында да, диянәт дөньясында да колак юк иде, күз юк иде.

(ضیاء لم یبن لعیون کمه * وقول ضاغ فی آذان صم)
(رأیت الحق لؤلؤة توارت * بلج فی ضلال الناس جم)[8]

---

[1] Чыганак: Муса Җаруллаһ. Ислам милләтләренә дини, әдәби, иҗтимагый, сәйәси мәсьәләләр тәдбирләр хакъкында. Берлин, 1923. Б. 3–31. (Өзек татар теленә тәрҗемә ителде).

[2] бәдбин – киләчәккә өметсез караучы; алдагыдан начарлык көтүче; пессимист.

[3] матдиятче – галәмнең бары тик матди булуын, матдәдән гыйбарәт булуын дәгъвалаучы, материалист.

[4] Нәхес әкбар – Иң олы бәла.

[5] вакыйг булырга – булырга, барлыкка килергә; чынбарлыкка ашырга.

[6] диянәт – дин; динлелек; яшәешнең дингә кагылышлы һәр яссылыгы.

[7] инкыйлаб – түнтәрелеш; революция.

[8] «Яктылык сукыр күзенә күренмәс, Сүз чукракның колагында юкка чыгар / Хакыйкатьнең кешеләрнең адашулары диңгезендә

Нәтиҗәдә, мәдәният дөньясының бик зур бозыклыкларына, бик яман гаделсезлекләренә, кешеләрнең дә борынгы гөнаһларына, иҗтимагый гөнаһларына, сәясәт һәм риясәт[1] турындагы хирысларының туймас өметләренә куәт мәйданнарында бөтен дәүләтләрнең ярышуларына зарури бер нәтиҗә, табигый бер нәтиҗә буларак, 1914 елда Мәдәният мөхарәбәсе[2], Бөтендөнья мөхарәбәсе башланды да; Бөек кыямәтнең иң олы дәһшәтләренә үрнәк буларак, дүрт-биш ел дәвам иткәннән соң, өлүһиять[3], диянәт, җәмгыять, дәүләт, интизам[4] дошманы анархист бәдбин Карл МаркСның җенни[5] чаралары белән әзерләнеп, үч алу ярсуы белән, бәдбинлек зәһәре[6] белән агуланган зур гаскәрнең, ягъни пролетарияләрнең олы куәте аркасында, каһарман куманданларының[7] кыю хәрәкәтләре бәрәкәтендә, куәтле ихтиляль[8], дәһшәтле революция, мәдәният дөньясының бөтен нигезләрен, бөтен әсәрләрен җимереп ату максаты белән башланды; Җиһан мөхарәбәсенең табигый бер нәтиҗәсе буларак туды. Ягъни: мәдәният мәркәзләрендә бәдбин Карл МаркСның дүрбин күзләре алдында ике ел элек йөренеп торган фетнә хыяллары – бүген дәһшәтле золмәтләре[9] эчендә, мәдәният гүрстаны[10] өстендә, куркыныч бер шәкелдә,– социализм киеменәрен киеп, коммунизм сурәте белән

---

яшерелгән энҗе бөртеге булуын аңладым» (әл-Мәгарринең «әл-Лөзүмият»еннән).

[1] риясәт – баш булу, идарә итү; хөкемдарлык.

[2] мөхарәбә – зур сугыш.

[3] өлүһиять – илаһият гыйлеме (теология) төшенчәсе: 1. Илаһилек; Аллаһлык; 2. Илаһият гыйлеме төшенчәсе, Аллаһның илаһлыгы, илаһилеге турындагы, аның ни рәвешле чынбарлыкка ашуы, ни рәвешле башкарылуы турындагы тәгълимат.

[4] интизам – тәртиплелек; әйберләрнең тәртиптә булуы; кагыйдәләр буенча эш итү.

[5] җенни – җеннәрдән булган; җеннәргә хас.

[6] зәһәр – агу; агулы.

[7] куманданкумандан – гаскәр башы; командир.

[8] ихтиляль – баш күтәрү, аяклану; чуалыш, бунт.

[9] золмәт – караңгылык.

[10] гүрстан – зират.

мәйданга чыгып,– Русиядә мәдәниятнең бөтен әсәрләрен, бөтен нигезләрен харап итте; ачлык-юклык аяклары белән бөтен кешеләрнең паймал итте[1], хөррият шигаре[2] белән, азатлык дәгъвасы белән бөтен диннәрне дә, бөтен тәгълиматларны да инкяр итте.

(Русия мәгариф ягы белән, сәнаигъ[3] һәм сәнагать[4] ягы белән мәдәни дәүләтләрнең һәрбереннән түбән булса да, артта калган булса да, инкыйлаб хәрәкәтләре өчен кирәкле булган фетнә куәте Русиядә гаять зур иде. Ихтиляль рәһбәрләре[5], революция дипломатлары хакыйкатьне ачык күреп, форсатны да ганимәт[6] дип белеп, һәр тарафдан ашыгып шуңа күрә Русия җиренә тупланды. Иң уңай бер җирлектә, сәгате тәмам килеп җиткән бер заманда инкыйлаб хәрәкәтләрен башлады)[7].

Мөхарәбә авырлыклары белән харап булган шәһәрләр, авыллар революция вәхшилеге белән тәмам таланып, гаиләләре дә харап булып, шәһәрләр-авыллар тәмам буш булып калды; интернационаллык исеме белән, милләтләрнең һәрбере: үзләре дә, диннәре дә, мәгъбәдләре[8] дә, мәхкәмәләре[9] дә, кануннары да – мыскыл ителеп, хәрби трибуналларның, фәукыл-гадә комиссияләрнең[10], (ЧКа) ларның рагыдлары[11],

---

[1] паймал итәргә – аяк астына атып таптарга.

[2] шигарь – сөрән; өндәү; (лозунг).

[3] сәнаигъ – сәнагать сүзенең күплеге.

[4] сәнагать – һөнәрчелек; промешленность, индустрия.

[5] рәһбәр – юлбашчы; юл күрсәтүче, әйдәп баручы; җитәкче, лидер.

[6] ганимәт – сугышта кулга төшерелгән (яулап алынган) дошман малы, трофей.

[7] Җәяләр төп нәсхәдә куелганнар. Әлеге өзекнең китапның мөхәррире Гаяз Исхакый тарафыннан язылган булуы ихтимал.

[8] мәгъбәд – илаһка табына торган урын (мәчет, храм һ.б.).

[9] мәхкәмә – мәхкәмә, суд.

[10] фәукыл-гадә комиссияләр – гадәттән тыш комиссия (чрезвычайная комиссия).

[11] рагыд – күк күкрәү.

яшеннәре эчендә, янар сарайларның зәфирләре[1] арасында, мәхкәмәләрнең, фабрикаларның хәрәбәләре өстендә яңа диннең яңа декалогы[2], коммунизм тәгълиматының «иман шартлары» һәрҗирдә кызыл ләүхәләргә[3] зур хәрефләр белән язылып игълан кыйлынды, тәрбия агуланды, түбәнгә тәгәрәде. Кешеләрнең табигатьләре янә вәхшәт хәлләренә кайтты, төште.

Ягъни, кешеләрнең күпчелегенә юклыктан, наданлыкдан, кимсетелүдән, хәерчелектән, каннан, күз яшеннән, мәшәкатьтән, тарлыктан, кайгыдан башка һичбер нәрсә, һичбер сәгадәт бирмәгән мәдәният низамнары[4], диянәт шәкелләре күпчелекнең кулы белән, интикам[5] куәте белән җимерелде. Борынгы гөнаһларның гадел җәзалары булды.

Русиядә күпчелекнең кулында, милкендә, күңелендә ни мәдәнияттән, ни диянәтдән бер өлеш юк иде, бер насыйп юк иде. Бары тик бәдбәхетлек[6], бары тик әсирлек бар иде, бары тик олы бер хурлык бар иде. Кулда сакланырлык бер әйбер юк иде, күңелдә сөелерлек бер әйбер юк иде, хыялда ирешергә теләнелгән бер өмет юк иде. Ләкин, нәфрәт ителерлек хәлләр һәр хосуста гаять күп иде, гаять чук иде.

Шуңа күрә, бәдбин карашларга бөтен рухы белән, бөтен акылы белән бирелгән, җиңелгән Карл Маркс кебек дәүләт һәм интизам дошманнарының, бөек анархистларның карашлары, рухлары, агитация юлы белән халыкның күпчелегенә гаять җиңеллек белән үтеп кереп, йогып, Русиядә һәрҗирдә дәһшәтле ихтиляль, куәтле революция җиңеллек белән башланды, тизлек белән таралды. Мәдәният низамнары хилафына[7] да, диянәт әдәпләре хилафына да, дин тәгълимнәре[8]

---

[1] зәфир – авыр итеп сулыш алу; аһ итү.

[2] декалог – исламнан әүвәлге сәмави диннәрнең дини-әхлакый гамәл кагыйдәләре.

[3] ләүхә – плакат, транспарант; ләүкә; такта.

[4] низам – тәртип; җайга салынганлык; система.

[5] интикам – үч; үч алу.

[6] бәдбәхет – бәхетсез; язмышы яман.

[7] хилаф – каршы; тискәре; туры килми торган.

[8] тәгълим – өйрәтү, гыйлемләндерү; белдерү;

хилафына да, шәригать[1] усульләре хилафына да яңа дин,– коммунизм дине,– Русиядә корал көче белән куәт алды, җиңүгә иреште.

Иске мәдәният, карт мәдәният үлде, үзенең гүренә үзе белән бәрабәр[2] бөтен әсәрләре дә, әйтик, күмелде. Бу тугрыдыр. Ләкин, Карл Марксның уйлаганы кебек, гүркян[3] пролетария,– мәдәният гүрен, буржуазия каберен казучы пролетария,– капитал кулы белән әзерләнмәде[4]. Бәлки мәдәниятнең золымы, (?) мәдәниятнең азгынлыгы, исрафаты[5], мәдәниятнең һичбер нәрсәдән туймас убыр тамагы, упкын карыны – үзенең гүрен, каберен пролетария кулы белән, золым көрәге белән казыттырды. Әүвәлге буржуазия диктатурасы урынына пролетария диктатурасын җирләштерде.

Әлбәттә, золым золмәттән башка һичбер нәтиҗә тудырмас. Истибдад[6] тышкы күренеш ягыннан да, күләм җиһәтеннән дә артты. Элекке истибдад бер азчылык кулында булса да, инкыйлабтан соң бүгенге истибдад икенче азчылык кулына күчте. Күпчелекнең хокукыннан мәхрум ителүе канун хөкеме белән булды.

Ягъни: иске бозыкларның, әүвәлге золымнарның табигый бер нәтиҗәсе, бер җәзасы буларак, бүгенге диктатура туды.

Юкса, әүвәлге хәлләрнең, борынгы низамнарның һәрберенә дошманлык, бәдбинлек күзләре белән караучы Карл Марксның күзаллавы кебек, мәдәниятнең фәннәренә, һөнәрләренә, сәнагатьләренә, машиналарына, диннәрнең гакыйдәләренә, әдәп-әхлакларына, тәгълимнәренә, усульләренә[7] кануннарына бер нәтиҗә төсендә булмады.

---

[1] шәригать – тар мәгънәдә: исламча яшәү кануннары; киң мәгънәдә: теләсә нинди кануннар системасы.

[2] бәрабәр – бергә, бергәләп, бергәлектә.

[3] гүркян – кабер казучы.

[4] ягъни, пролетариат капитал кулы белән әзерләнмәде.

[5] исрафат – чаманы белмичә мал тузгыту, исраф.

[6] истибдад – золым; гаделсезек; деспотлык.

[7] усуль – тамырлар; асыллар; нигезләр.

Гүрстаныбыздан калкып, күзләребезне ачып карасак тарихның шушы көннәре бөтен Русия дөньясы өчен тәмам кыямәт булды.

(آسمان میگفت این دم بازمین * گرقیامت را ندیدستی ببین)[1]

Гамәлләренең дәфтәрләре газаб кыйлучы зобаниларының[2] куллары белән кешеләрнең һәрберенә сул тарафлардан берелеп, кара сәхифәләрнең йөзендә кызыл канлар белән язылган күптәнге гөнаһларының гадел җәзалары да җир йөзенә каһәр кыйлучы күкләрдән бөтен дәһшәте белән яңгыр кебек явып; кешеләрнең һәрберен: мөҗримнәрне[3] дә, гаепсезләрне дә – хисаб тоту мәйданнарына, нәүбәт сафларына сөрде.

Мондый зур кыямәт соңгы елларның котылгысыз һәм табигый бер нәтиҗәсе иде.

Сәясәт дөньясында иң олы, иң куәтле дәүләтләр ике тараф иде: 1) Инглиз, Фирансия, Русия тарафы; 2) Алмания тарафы.

Гаять куәтле бу ике тараф һәр сәясәттә, хосусан, Шәрык сәясәтләрендә Иран җирләрен, Төркия мәмләкәтләрен[4], Төркия белән Иран бәрәкәтләрен тулысынча яулап алу хирысларында бу ике тараф мөсәбакада иде; һәр җиһәтлә хазирлек[5] һәрбер тарафда тәмам иде, хазир иде.

Мәдәният дөньясында икътисад мәсьәләләре дә бөек бохран[6] туфаннары эчендә иде. Карл Маркс кебек дәүләт дошманнарының бәдбин икътисад галимнәренең гаять тәэсирле тәгълимнәренә, агитацияләренә икътисад бохраннары бәрәкәтле туфрак булып, кешелек дөньясында зур ихтиляльнең куәтле галимнәре мөһлик[7] гонсырлары[8] тәмам әзерләнгән иде.

[1] тәрҗемәсе: «Бу чакта Күк Җиргә: «Әгәр кыямәтне күрмисең икән сукырсың!» – дия иде».

[2] зобани – җәһәннәмгә эләккәннәрне җәзалый торган затлар.

[3] мөҗрим – җинаятьче.

[4] Төркия мәмләкәтләренә – Госманлы Дәүләт-и Галиясенең biləмәләре күздә тотыла.

[5] хазир – әзер, әзерләнеп беткән.

[6] бохран – куркыныч вазгыять; кризис.

[7] мөһлик – һәлакәткә илтүче; үлем белән тәмамланучы.

[8] гонсыр – нинди дә булса матди җисемнең аерылгысыз өлеше;

Ком бөртекләре кадәр күп булган ислам милләтләре, ком кебек таркау бер хәлдә калып, күбесе мәдәни дәүләтләрнең кулында әсир иде.

Инглиз, Фирансия, Русия кебек олуг дәүләтләрнең көчле тәэсирләре, куәтле һөҗүмнәре астында гасырлар дәвамында яшәп, сугыштан сугышка, инкыйлабтан инкыйлабка ава-түнә килгәннән соң; социалистларның раһбәрләренә гүзәл революция үрнәкләреннән гыйбрәтле дәресләр биреп, бүгенге гомуми сугышта Русия инкыйлабына юл ачучы Төркия дәүләте – мәмләкәтнең эчке исляхатенән[1] соңгы гасырларда гаҗиз[2] калып, бәлки тәмам гафил калып; һәм Төркия дәүләтенә, һәм бөтен ислам мәмләкәтләренә, әлбәттә, файда бирәчәк исламият сәясәтеннән дә тәмам гафил калды, бәлки хилафына, тәмам зарарына хәрәкәт итте, хәрәкәт итәр иде.

Шаригъ[3] хәким, галәйһис-саләт вәс-сәлам, хәзрәтләренең хәлифәсе булган, ислам кыйбласының сахәбәсе һәм Рауза-и сәгадәтнең хезмәтчесе, өч хәрәмнең[4] мәликәсе булган, Гарафәт белән Мина җамигъларының[5] рәисе һәм Коръән кәрим имамы булган Төркия Дәүләт Галиясе ислам милләтләренең калебләренә үзенең тәэсирен, милләтләренең ихтирамнарын тәэмин итә алмады.

---

матди галәмнең элементлары; нәрсәнең дә булса табигате, асыл сыйфаты.

[1] исляхат – нәрсәне дә булса яхшырту, камилләштерү йөзеннән башкарыла торган үзгәртүләр; үзгәртеп кору, төзекләндерү; дөресләү.

[2] гаҗиз – көчсез, зәгыйфь.

[3] шаригъ – кануннар булдыручы, шәригать яки яшәү кагыйдәләрен гамәлгә куючы; сүз, гадәттә Аллаһ тәгалә яки Мөхәммәт пәйгамбәрне белдерә.

[4] хәрәм – тыюлык; өйнең ятлар өчен ябык өлеше; гыйбадәтханә. Биредә Мәккәдәдәге Кәгъбә, Мәдинәдәге Мәсҗид ән-Нәби һәм әл-Кодестәге (Иерусалимдагы) Куббат әс-сахра исемле гыйбадәтханәләр күздә тотыла.

[5] җамигъ – каланың, авылның үзәк җамигъ мәчете.

Бу хәл, шөбһә юк, хөкүмәтнең, мәшихәтнең[1] гаять тирән гафиллеге, гафу кыйлынмаслык бер гөнаһы иде.

Бөтен әһле исламның йөрәкләренә тәэсир итүче шулкадәр олы вә мөкаддәс куәтләргә ия була алмаса да, әһле исламның калебләрен хилафәт[2] мәркәзенә баглау сәясәтләреннән хөкүмәтнең, мәшихәтнең гафиллекләре, минем карашымча, олы бер җитешсезлектер.

Ислам мәмләкәтләренең Төркиядән башкаларына тәкъдим каләме ул вакытларда гамәлдә түгел иде дә. Бу мөляхәзамны[3] Төркия хөкүмәтенә һәм мәшихәт исламиясенә атап юлладым.

Бүгенге Җиһан мөхарәбәсендә гарәпләрнең гыйсьяннарына, фетнәләренә[4]; кайбер әдәпсез Һиндестан мөселманнарының Төркиягә каршы мөхарәбәләренә хөкүмәтнең, мәшихәтнең гафиллеге бәһанә[5] булмаса иде, яки сәбәп булмаса иде, андый бер мөляхәза бүген безнең исебезгә төшмәс иде.

Былтыр, ноябрьнең 14дә, Хилафәт исламия[6] теле белән, мәшихәт исламия хитабы белән нәфир-е гам[7] буларак, бөтен исламият дөньясына гомуми җиһад игълан кыйлынган иде.

[1] мәшихәт – Госманлы дәүләтендә иң абруйлы дин әһелләреннән гыйбарәт булып, империя кимәлендә дин эшләре белән идарә иткән дәүләт оешмасы.

[2] хилафәт – яшәеше, хөкүмәт вә идарәсе, иҗтимагый төзелеше, икътисады, мәдәнияте, мәгарифе, эчке һәм тышкы сәясәте ислам вә шәригать кануннары буенча оештырылган дәүләт.

[3] мөляхәза – фикер йөртү; тирәнтен уйлау.

[4] Беренче бөтендөнья сугышы (Җиһан мөхарәбәсе) елларында (1916–1918) Госманлы Дәүләти Галиясенең Хиҗаз, Шам, Гыйрак кебек вилаятьләрендә яшәгән гарәп кабиләләренең бер өлеше, инглизләрнең үсендерүенә күнеп һәм алардан китерелгән кораллар белән коралланып, Гарәби Лоуренс (Лоуренс Аравийский) исемле инглиз агенты җитәкчелегендә Госманлы иленә каршы гыйсьян башлыйлар. Нәтиҗәдә, Антанта илләренә каршы аяусыз сугыш алып барган төрекләр илнең Якын Көнчыгыштагы биләмәләрен югалталар.

[5] бәһанә – сәбәп; сылтау.

[6] Хилафәт исламия – ислам хәлифәлеге, ягъни ислам дине хөкемнәренә корылган дәүләт.

[7] нәфир-е гам – халыкны аякка бастыру өчен сөрән салу.

Моңа карамастан, ислам һәм төрек дошманнарының сәваден[1], сафларын ислам гаскәре, төрек гаскәре ишәйтте.

Соң дәрәҗә чиркандыргыч бу хәлнең, әлбәттә, бер сәбәбе бар.

Мин тануымны белдерәм һәм кыйлык белән дәгъва итәм ки, әһле исламның аерым алынган вәкилләрендә иман бар исә дә, Төркия дәүләтенә бөек бер мәхәббәт ислам вәкилләренең һәрберендә бар исә дә, галәме исламны гомумән алганда иман юк, ислам юк.

Шуңа күрә, һәм дә исламият, хилафәт сәясәтләреннән, ислам дөньясының дини, әдәби, иҗтимагый хәлләреннән хөкүмәтнең һәм мәшихәтнең тәмам гафиллекләренә күрә, бүгенге гомуми мөхарәбәдә ислам гыйззәте, әһле исламның хөрмәте, әһәмияте, ислам дәүләтләре – үзләренең куллары белән хәрабә кыйлынды.

Кадердә инсаният[2] дөньясына, бүгенге мәдәниятнең бүгенге хәятенә һәлак булмак язылган булса да, сәясәт хәрәкәтләренең, икътисад бохраннарының котылгысыз бер нәтиҗәсе буларак, олуг дәүләтләрнең һәм бөтен милләтләрнең гомуми мөхарәбәләре 1914 елда игълан кыйлынды.

Дөрес, мөхарәбә максат түгел исә дә; ләкин коткарылу кебек, гыйззәт[3] һәм бәйсезлек кебек, хакыйкать һәм хокук кебек олы һәм иң мөкатдәс максатларның бердәнбер чарасыдыр; кешеләрнең табигатьләренә, куәтләренә нисбәтән моңа башка бер чара юк, зарурәт[4] хөкеме белән мөхарәбә барлыкка килгәннән соң, мөхарәбә, әлбәттә, тиешле кыйлыныр, фарыз булыр, бәлки гыйбадәт улур.

(لاتتمنوا لقاء العدو. وسلوا الله العافية. ولكن اذا لقيتم فاثبتوا واصبروا واعلموا ان الجنة تحت ظلال السيوف)[5]

[1] сәвад – каралык; биредә: җирлек; биләмә.

[2] инсаният – кешелек дөньясы; цивилизация.

[3] гыйззәт – кадер, хөрмәт; көч, куәт; дәрәҗә.

[4] зарурәт – чарасызлык, котылгысызлык; ирексезлек, мәҗбүрилек.

[5] Хәдиснең тәрҗемәсе: «Дошман белән көрешүне теләмәгез. Аллаһтан исәнлек-иминлек сорагыз. Әмма [дошман белән] очрашсагыз нык вә сабыр булыгыз, һәм җәннәтнең кылычлар күләгәсендә

Шуңа күрә, «Мөляхәза» исемле китабымда мөхарәбә игълан ителгән минутта мондый сүзләр язган идем:

«Мәдәният дөньясы дәһшәт Миналарында, гыйззәт мөхарәбәләренә бүген гаять күп, гаять олы корбаннарын тәкъдим итәләр. Илаһи гаделлек кәгъбәләрендә ул олы корбаннар, әлбәттә, кабул кыйлыначак».

«Ул бөек гыйбадәттә катнашу, йә әйдәп бару шәрәфеннән[1] исламият дөньясы бүген мәхрумдыр». «Моның белән бәрабәр[2], нәтиҗәдә, иң зур югалтулар әһле исламның муеннарына йөкләнәчәк». «Мәдәни милләтләр бәйсезлек шәрәфләренә, риясәт тәхетләренә, гыйззәт җәннәтләренә ирешү арзусы[3] белән, миллион-миллион җаннарын, миллиард-миллиард малларын корбан итеп; сабыр сиратлары өстендә җәһәннәм чокырларына да китеп, хурлыктан, коллыктан котылу максаты юлында һәммә авырлыкларны кичәрләр».

Бу ун-унбиш юлдагы уйларымны мөхарәбә игъланы дәкыйкасында[4] «Мөляхәза» исемле китапның әүвәлге сәхифәләрендә язмыш идем.

Бары тик башкаларның максатларына хезмәтче булу сыйфаты белән, үзләренең гыйззәтләрен, хөрмәтләрен, диннәрен, йортларын җимерү хосусларында куәтле корал булу хурлыгы белән, бөтен исламият дөньясы да бүгенге мөхарәбә хәрәкәтләренең, мөхарәбә дәһшәтләренең беренә һәр җәбһәдә[5], һәр фронтта катнашты.

Исламият байраклары, төреклек кылычлары бары тик Төркия Дәүләт-и Галиясе кулында калды, зарурәт икътизасы[6] белән, бәлки Коръән кәрим фәрманы белән төрек хөкүмәте дә гомуми мөхарәбә дәһшәтләренә катнашты. Битараф калу

---

булуын белегез» (әл-Бохари, «Җиһад», 22; Мөслим, «Җиһад», 20).

[1] шәрәф – хөрмәт; намус; кадер, дәрәҗә, мәртәбә.

[2] бәрабәр – бергә, бергәләп, бергәлектә.

[3] арзу – теләк, омтылыш.

[4] дәкыйка – сәгатьне тәшкил иткән вакыт берәмлеге, сәгатьтәге 60 өлешнең берсе; бик кыска вакыт, мизгел; минут.

[5] җәбһә – дошманнар йөзгә-йөз килгән сызык, фронт.

[6] икътиза – кирәклек; таләп итү; кушу; теләк.

мөмкин булса иде, бәлки битараф та калыр иде, ләкин мөмкин түгел иде. Катнашу, әлбәттә, зарури иде, мәҗбүри иде.

Ислам дәүләтләренең иң бөек дошманнары – Русия, Фирансия, Инглиз, Италия – бер тарафта иделәр. Алмания ялгыз калган булса иде, аз заман эчендә җиңелеп; ислам дошманнары Төркия дошманнары җиңсәләр иде; Төркия дәүләте, Иран мәмләкәте, ислам җирләре дошманнарның кулында тулысынча бүлгәләнеп бетәр иде; гамәләләрнең[1] капитал пәнҗәсеннән[2], пролетариялөрнең буржуазия әленнән[3] котылулары да һичбер сурәттә мөмкин булмас иде.

Төркияне тәмам бетермәк өметләрен үзенә мөкатдәс бер максат иткән Русия дәүләтенә дә, бөтен ислам мәмләкәтләрене үзенә әсир иткән Инглиз дәүләтенә дә Төркия һичбер сурәттә мөхарәбә рафикы[4] була алмас иде. Ягъни, ике тарафтан берен сайлап алу мәҗбүрияте ул чакта табылса иде, сайланылачак тараф, әлбәттә, күз алдында иде.

Шуңа күрә, Төркия Дәүләт-и Галиясе, зарурәт икътизасы белән дә, мәсълихәт мөляхәзасы белән дә, Алмания тарафдары булып, катнашты. Сугыш игъланыннан бер-ике көн элек, Алмания императорының кайгыртуы белән булса кирәк, Төркия-Алмания могаһәдәсе[5] дә имза кыйлынды. Могаһәдә куәте белән дә Төркия Дәүләт-и Галиясе Алмания тарафында калды.

Мөмкин булса иде, ашыкмас иде, бераз сабыр итеп, тарафларның берсенә соңрак кушылыр иде. Мөмкин булмады. Сугышның беренче елында, беренче айларында Алмания хәрбиясенең фәрманы белән, чара күрүе белән Русия шәһәрләренең берсе тупка тотылып, Төркия тарафыннан сугыш игълан ителгән кебек эшләнде. Төрекләрнең бу хакта белемнәре-хәбәрләре юк иде. Русия хөкүмәтенә тәрзыя[6] юлы

[1] гамәлә – эшчеләр; пролетариат.

[2] пәнҗә – кул.

[3] әл – кул.

[4] мөхарәбә рафикы – сугыш аркадашы, союзник.

[5] могаһәдә – сүз бирешү, вәгъдәләшү; килешмә; договор.

[6] тәрзыя – ризалату; ризалыкны күрү; китергән зыянны төзәтүне

белән төрекләрнең мөрәҗәгатьләре дә мәгърур Русия хөкүмәте тарафыннан кабул кыйлынмады. Шул рәвешле, 1914 елның ноябрендә сугыш игълан кыйлынган кебек игътибар кыйлынып; Төркия Дәүләт исламиясе Алманиянең шәриге[1] булды. Бу адым Төркия сәясәтенең ихтыярларыннан читтә торган бер зарурәт иде, шуның белән бергә бер зур дөрес эш иде. Төркия бугазларны япты; Русия үзенең сугыш тарафдарларыннан ярдәм ала алмыйча, ахыр читтә җиңелде. Истанбул бугазларын ачу өчен, 14нче елның ахырында бөтен дөнья куәте Чанак кальгасенә һөҗүм итте. Кораллары бөтенләй булмаган Төркия ялгыз үзе, ялгыз төрекләр иң бөек дәүләтләрнең иң мөкәммәл бәрри[2] һәм бәхри[3] куәтләренең һәрберсенә кадәр каршылык күрсәтеп; исламиятнең гаять ачык бер могъҗизасы, иманның да гаять бөек бер куәте буларак Төркия бөтен дөнья куәтләрен җиңде, үзен яклый алды. Җир йөзендә, инсаният тарихында мондый көчле зур сугыш, шулкадәр гаҗәеп олы җиңү юк булса кирәк.

Иманлы төрек гаскәренә бөек бер дандыр, Төркия тарихына әдәби бер шәрәфдер, мәңге дәвам идәчәкләренә катгый бер бәшарәттер[4].

Чанак кальгасында төрек ислам гаскәреннән дүрт йөз мең корбан! Өч йөз меңе шәһит булды. Әлбәттә, бу чамалы бер хисап. Исемнәре, даннары Бәдер шәһитләренең дәфтәренә исламият каләме белән, әлбәттә, язылып куелды. Хөрмәтле изге исемнәре, ислам милләтләренең калебләренә дә язылып, ислам минбәрләрендә, төрек касыйдәләрендә мактау теле белән мәңге зикер кыйлыначак[5].

Мөмкин булса иде, Алмания куәте белән Төркия куәте Һиндыстан өстенә, Мисыр өстенә көллиятле[6] куәтле гаскәр

---

үз өстеңә алу.

[1] шәрик – иш; туар ише; иптәш, компаньон.

[2] бәрри – хәрби җир көчләре.

[3] бәхри – хәрби диңгез көчләре.

[4] бәшарәт – сөенче; шатлыклы хәбәр.

[5] зикер кыйлырга – искә алырга, телгә алырга.

[6] көллиятле – бөтен яктан җитешкән; тулы.

юллап; башта инглиз мәсьәләсе хәл кыйлынса иде; Билҗика-Вәрдән[1] җәбһәләрендә Алмания кебек куәтле бер дәүләтнең шулкадәр көллиятле куәте файдасыз исраф кыйлынмаса иде; Америка кебек куәтле бөек бер дәүләт хакында акыллы, күркәм бер сәясәтне Алмания хөкүмәте куллана алган булса иде; бүгенге гомуми мөхарәбәдән инсаният дөньясы да, исламият дөньясы да, бәлки, башкача файдаланырлар иде.

Сәясәтләренең хаталарымы иде, үзенчә эш итүче тәкъдирнең[2] зарури бер казасымы[3] иде, ничек булса да, булды; бөтен җир йөзен гүрстанга әйләндергән бүгенге сугышның соңгы еллары сәяси, иҗтимагый, әхлакый инкыйлабның иң яманнарына юл ачты.

Сугышның өченче елында, Төркия гаскәрләренең иманы һәм куәте хозурында, рус чарлыгы[4], Русия кайсарлыгы[5] җимерелде, арадан чыкты. Айа Суфия гөмбәзләренә һәм манараларына салиб[6] куярга җыенган ак рус дәүләте, кыяматкәчә күтәрелмәс рәвештә, берничә миллион рус «лашәләре»[7] астына күмелеп; исламият һиляльләре[8] өстенә, Айа Суфия манаралары өстенә кадалачак рус кричләре чарлык[9] гүрләре өстендә калыкты.

Русия гаскәренең һәр җәбһәдә гаять хурлыклы җиңелүе, хөкүмәтнең һәм дәүләтнең тәмам тулысынча бөлүе, бөтен вилаятьләрдә гаять дәһшәтле бәһалелек бәлаләре,– гаять куәтле бу өч гамәл,– Русия вилаятьләрендә дәһшәтле инкыйлаб туфаннарын тудырды.

Дүрт-биш ел эчендә үзенең бөтен куәтләрен тулысынча исраф иткән Алмания дәүләте, ахырда, Америка вә Инглиз дәүләтләренең сау-сәламәт дәһшәтле куәтләре хозурында җиңелде. Бу эшнең хакыйкый сурәте дә, сәбәбе дә миңа бу

[1] Билҗика-Вәрдән – Бельгия-Верден.

[2] тәкъдир – очрак; ихтимал.

[3] каза – язмыш; тәкъдир.

[4] чарлык – царь идарәсе.

[5] кайсарлык – царизм.

[6] салиб – хач.

[7] лашә – үле гәүдә; үләксә.

[8] һиляль – яңа туган ай; айның беренче чиреге.

[9] чарлык – падишалык; царьлек.

дәкыйкада мәгълүм булмаган гаять сәер үзгәрешләр сугыш хәрәкәтләрендә күренә башлады.

Алманнарның мәгъррур сәясәте шомлыгында Инглиз, Фирансия, Италия тарафына Америка дәүләте дә кушылды. Дошман һәр җиһәттә: сан җиһәтеннән белән дә, техника җиһәтеннән дә, корал җиһәтеннән дә, хаҗәтләре җиһәтеннән дә, бәррия-бәхрия куәт җиһәтеннән дә – ачыктан-ачык сурәтдә өстенлеккә иреште, Төркия, Алмания, Авустрия, Болгария бөтен дәүләтләрнең иттифакы[1] хозурында аблука[2] вазгыятендә калды. Инглиз белән Фирансия тарафына Америка дәүләте дә кушылганнан соң, мөдһиш[3] мөһлик бөек бер куәт Алмания өстенә басты. 1918 ел ахырларында Болгария урдалары бердән-бергә җиңелеп, Төркия мөттәфикълары[4] араларына дошман буларак сугылды, керде. Австриядә, Маҗаристанда[5] ихтиляль башланды, инглиз мәкер коручыларының куәтле мәкере белән Алман милләтендә хөкүмәтенә карата да, баш куманданларына карата да ышанмау хасыйл[6] булды, дошманлык башланды, фронтларда Алман гаскәрендә ихтиляль чыкты, ачык гыйсьян башланды.

Мөттәфикъларның эчтә ихтиляльләрен, тышта җиңелүләрен Төркия ачык күрде. Ислам мәмләкәтләреннән тәмам аерылып калган Төркия Дәүләт Исламиясе бу юлы үзенең мөттәфикъләреннән дә тәмам аерылып калды, мөхарәбәне Төркия бары тик үзе дәвам иткән булса, Төркия җиңелүе дә гаять ихтимал иде.

Шуңа күрә, Инглиз тарафыннан гарыз[7] кыйлынган мөтарәкә[8] хурлыкларын Төркия ул чакта мәҗбүри сурәттә кабул

[1] иттифакъ – бердәмлек, бер карашка килү; үзара килешү.

[2] аблука – тышкы дөнья белән аралашырга мөмкинлек бирмәгән сурәттә камап алу; блокада.

[3] мөдһиш – куркыныч; куркыта торган; коточкыч.

[4] мөттәфикъ – сугыш тарафдары; килешүче.

[5] Маҗаристан – Венгрия.

[6] хасыйл – барлыкка килү.

[7] гарыз – тәкъдим; каршыга чыгарып кую.

[8] мөтарәкә – үзара сугышучы тарафлар арасындагы вакытлы килешү.

итте. Мөтарәкә гаскәрнең җиңелүе аркасында түгел, бәлки тышкы әхвәлнең таләбе белән иде.

Чанак кальгасында бөтен дөнья куәтләрен җиңгән Төркия, нәтиҗәдә, тышкы әхвәлнең, эчке әхвәлнең таләбе белән тышкы дошманнарның каршысында тәмам ялгыз калып, үзенең мөттәфиткъларыннан да, ислам мәмләкәтләреннән дә тәмам аерылган хәлдә калып; мөтарәкә хурлыгына мәҗбүр калды, мәҗбүр булды.

Шулай итеп, җиңү Инглиз тарафына күчте. Алмания, Төркия дәүләтләре белән бәрабәр, бөтен исламият дөньясы да, 1918 елның ахырында, Мәрмәрә диңгезе өстендә, 22 маддәдән гыйбарәт булган җиңелү могаһәдәләрен имзалады.

Мөтарәкә маддәләре Фирансиядәге Сәвер шәһәрендә ахырда могаһәдә сурәтенә әйләндерелеп, Төркия-Антанта могаһәдәсе булды. Сәвер могаһәдәсе исеме белән мәшһүр булса да, аның хакыйкый тәфсыйлате[1], маддәләре миңа би лә васита[2] мәгълүм булмады. Эзләдем, тик таба алмадым.

Төркия раһбәрләренең бәяннарына[3] күрә, Төркия җәридәләренең[4] хәбәрләренә вә мәкаләләренә күрә, Сәвер могаһәдәсе могаһәдә түгел, бәлки дәүләтне дә, хилафәтне дә тәмам бетереп, Төркия җирен тулысынча яулап алып Төркия җирен бүлгәләү иде. Сәяси, икътисади, иҗтимагый сурәттә әсирлек маддәләреннән гыйбарәт иде. Мәмләкәт белән идарә итү дә, аны химая[5] кыйлу да башкаларның ихтыярларына тапшырылачак, дәүләтнең бөтен хәрби куәте, куәт бәррияce вә бәхриясе, кораллары һәм гаскәре Антанта ихтыярына тапшырылачак; Шам, Сүрия җирләре Фиранса химаясендә яки Инглиз химаясендә калып, яһүд дәүләтенә мәркәз кыйлыначак; Анатул кебек бәрәкәтле ислам җирләре Әрманстан кыйлынып, Гыйрак вилаятьләре дә мөстәкыйль бер имарәт[6]

[1] тәфсыйлат – җентекләүләр, җиренә җиткереп аңлатулар.

[2] би лә васита – арадашчысыз; турыдан-туры.

[3] бәян – хикәяләү; сөйләү.

[4] җәридә – газета.

[5] химая – яклау, саклау; берәүнең кулы астында саклану.

[6] имарәт – дәүләт белән идарә итү шәкеле; әмир тарафыннан идарә ителә торган биләмә, әмирлек.

кыйлынып; Америка белән Инглиз химаяләренә калдырылачак иде. Төркия кулында һичбер ихтыяр калмыйча дәүләтнең өмүр[1] малиясе[2] дә, өмүр икътисадиясе дә, өмүр сәясиясе дә, өмүр хәрбиясе дә тулысынча Антанта кулында, Антанта ихтыярында калачак. Сәвер [килешүендәге] маддәләренең рухы да, нәтиҗәләре дә, хәтта ачык гыйбарәләре дә бу юлда иде. Могаһәдәнең иртәгесе көнендә татбикать[3] башланды, Төркия мөхарәбә хәленнән дә яманрак вә начаррак бер хәлдә калды. Төркия мәктәпләре, банклары, идарәләре, ширкәтләре тәмам ябылды; төрекләрнең кулларыннан кораллары алынып, әрмәниләргә, юнаниларга бирелә башлады…

Октябрь инкыйлабыннан соң, шартлары гаять авыр мондый бер могаһәдә Брест-Литовскида совет хөкүмәтенә дә тәкъдим ителгән иде. Могаһәдә маддәләрен тулысынча үтәүдән Алмания хөкүмәте, Алмания дәүләте ул вакытта, әлбәттә, гаҗиз иде. Могаһәдә шартларының һәрберен, шуңа күрә, совет хөкүмәте ул вакытта зур кыюлык белән кире какты[4]. Хәтта үзенең гаскәрен дә, башыбозык гаскәрен дә бөек алманның, мәгърур алманның җиңелүгә дучар ителгән куәтеннән истиһза[5] юлы белән совет хөкүмәте таратты, таркатты.

Ләкин бөтен куәте белән Истанбулның өстенә дә, Төркия җирләренә дә истиля[6] иткән Антанта дәүләтләре могаһәдә маддәләренең һәрберен тәнфиз[7] итәчәк булыр исә, моның өчен куәтләре бар иде, кодрәтләре бар иде. Бугазлар тәмам ачык иде, бөтен хәрби диңгез көчләрен Төркия ярларына һәрвакыт юнәлтә алалар иде. Алмания үзенең таләпләре, маддәләре хозурында ул вакыт гаҗиз иде исә дә; Антанта,

---

[1] өмүр – эшләр; әмерләр.

[2] өмүр малия – финанс эшләр.

[3] татъбикать – яраштырулар, килештерүләр.

[4] Мөхәррирнең бу фикере тәмамән хатадыр. Савит хөкүмәте Брест Литовски могаһәдәсендә алманларның бөтен шараитыны гайнән кабул итмешдер. Мөсаххих.

[5] истиһза – мыскыллап көлү; мыскыл итү; хурлау.

[6] истиля – басып алу; яулап алу.

[7] тәнфиз – йөкләнгән вазифаны үтәү.

хосусан Инглиз, үзенең фәрманнары вә тәклифләре[1] хозурында тәмам куәтле иде.

Шуңа күрә, гаять фахиш[2] шу ике могаһәдә арасында гаять бөек вазгыять фәрыклары[3] бардыр.

Алмания таләпләрен Совет хөкүмәте рәдд итәчәк булса да, кабул итәчәк булса да, биредә һичбер куркыныч булмавы йөзеннән, биредә Советның бер тәдбире[4], бер кыюлыгы юк иде. Русия җире ят дошманның һөҗүменнән, истилясеннән ул вакыт тәмам азат иде. Төркия җиренә бөтен куәте белән бәреп кергән итмеш Антанта таләпләрен Анатул төрекләре кыю сурәттә кире какты; иске хөкүмәт әсирлек хурлыкларын кабул итсә дә, иманлы төрек милләт нәҗибәсе[5] дәүләтнең, ватанның коткарылуы юлында тәдбир күрүдән гаҗиз калмады. Ул тырышты, гаять шәрәфле сурәттә милләт мөвәффәкъ[6] булды.

Брест могаһәдәсе имза кыйлынганнан соң, тышкы мөхарәбәләр урынына бөтен Русия эчке мөхарәбәләр мәйданына әйләнде. Буржуазия, пролетария дәгъвалары белән шәһәрләрнең һәрбере фетнә учакларына әйләнде. Нәтиҗәдә, Русия дәүләте, дә Русия милләтләре дә харап булды.

Ләкин могаһәдәнең иртәгесе көнендә могаһәдәне гамәлгә ашыру Антанта куәте белән башланып, Төркия җире Антанта кулында әсир калып, һәр шәйдән, һәр куәттән тәмам мәхрүм кыйлынганнан соң, төрекләрнең милли куәтләре Антанта дәүләтләренә каршы сугыш башлады. Антанта вәхшәте белән Измир фаҗигаләре, Истанбул матәмнәре кебек дәһшәтле хадисәләр вакыйг булса да, Төркия җирендә эчке фетнәләрдән һичбер әсәр күренмәде. Истанбулда Антанта кулында әсир кебек калган иске хөкүмәт сабыр итсә дә, бөтен милләт белән бәрабәр инкыйлаб хөкүмәте сугыш дәһшәтләрен могаһәдә

---

[1] тәклиф – тәкъдим итү; боеру, әмер итү.

[2] фахиш – начар, бозык; чиктән чыккан.

[3] фәрык – аерма, үзгәлек; аеру.

[4] тәдбир – эшне ахырын уйлап эшләү; алдан күрү; тиешле чара.

[5] нәҗиб – тәрбияле нәселдән булу; аксөяк булу.

[6] мөвәффәкъ – уңышлы; бәхетле.

зилләтләреннән[1] өстен күреп; ислам мәмләкәтләренең, ислам милләтләренең нәҗатләренә[2], истикъляльләренә[3] бер тәдбир буларак, милли куәт хәрәкәте, хәрәкәтләрнең бәрәкәтле бәсмәләсе[4] башланды.

Мәгърур ике дәүләт тарафыннан мәгълүб[5] ике дәүләткә тәклиф кыйлынган гаять фахиш ике могаһәдә ике мәмләкәттә капма-каршылыклы ике нәтиҗәнең барлыкка килүенә китерде.

Тышкы дошманнары булмаган Русиядә дәһшәтле фетнәләр, мөхарәбәләр башланды. Тышкы дошманнары гаять куәтле булган Төркиядә куркусыз, акыллы, гайрәтле милли куәтләрнең хәрәкәтләре башланды.

Ачык катгый мондый иҗтимагый әхвәлдән мәгъкуль[6] бер нәтиҗә чыгару мөмкин булса, Төркия дәүләте, Төркия милләте файдаларына гаять зур, гаять мөһим, гаять тугры нәтиҗәләр чыгар.

Төркия дәүләте иҗтимагый һәм сәяси куәт җиһәтеннән Русия дәүләтеннән нык, өстен. Төрек милләте Русиядәге милләтләрнең һәрбереннән әдәби-иҗтимагый әхлак җиһәте белән югарыдыр. Төркия җире табигый бәрәкәтләре җиһәте белән Русия җиреннән байрактыр. Шуңа күрә, иң дәвамлы мөхарәбәләрне дә кичерә алыр; иң зур инкыйлаб көннәрендә дә фетнәләргә дучар булмас. Ислам әдәбе, төрек иманы, төрек өммәте – бу хакта гаять куәтле тәэминдер.

Брест могаһәдәсе, Версаль могаһәдәсе, Сәвер могаһәдәсе кебек могаһәдәләрнең сугышларны озайтудан башка зарури бер нәтиҗәләре юк исә дә, ислам дөньясына нисбәтән Сәвер могаһәдәсенең (Антанта-Төркия могаһәдәсенең) биргән гаять ачык гыйбрәтле бер сабагы бар: ул ислам дәүләтләре хакында

[1] зилләт – хурлык; түбәнлек.

[2] нәҗат – коткарылу; котылу, исән калу.

[3] истикъляль – бәйсезлек, ирекле булу; мөстәкыйль булу.

[4] бәсмәлә – бисми Аллаһи әр-рахмани әр-рахим, дигән гыйбарәне белдергән кыскартма.

[5] мәгълүб – җиңелгән.

[6] мәгъкуль – акыллы; акылга каршы килми торган; акылга сыя торган; урынлы.

Инглизнең назарын[1], гакыйдәләрен ачыктан-ачык белдерә. Америка кебек, Инглиз кебек куәтле мәдәни дәүләтләрнең бүгенге гомуми мөхарәбәгә караган асыл максатларын да ачыктан-ачык бәян итә.

Мәгъкуль бер сәясәтне үткәрәчәк тәкъдирендә бөтен исламият дөньясында хәлифәлеге дә кабул кыйлына алачак Төркия Дәүләт-и Галиясенең төрек кебек гайрәтле, кыю бер милләтнең куәтле бөек бер ислами дәүләт булып, сәясәт мәйданнарында мәңгелек дәвам итүе Инглизнең газаматына, Мисыр, Һиндыстан кебек бәрәкәтле ислам мәмләкәтләрендә Инглизнең хуҗа булуына зур бер хәтәр булыр иде, мөһлик бер хәтәр була алыр иде.

Русия кебек садә һәм зур бер дәүләтне үзенең мәкерләренә, үзенең сәясәтләренә корбан иткәннән соң, Төркия кебек куәтле бер дәүләтне йотмак, хилафәт хәтәрләреннән котылмак Инглизнең минминлеге, газаматы өчен иң зарури бер тәдбир, һәм дә сәгате-минуты тәмам җиткән яхшы бер форсат иде. Төркия җирләренә, Иран җирләренә истиля итү хирыслары, арзулары мәдәни дәүләтләрнең һәрберендә бар иде, куәтле иде. Бәлки гасырыбыз сугышларының һәрбере Шәрык җирләренә, Иран, Төркия бәрәкәтләренә истиля хирысы белән була иде. Бүгенге гомуми мөхарәбәдә Антанта тарафы җиңгән кебек булып, электән килгән хирыслары, әүвәлге шәһвәтләре тагын да куәтләнеп, мөгаһәдәләренең маддәләрендә Төркия җирләрене тәкъсим[2] иттеләр.

Бу җиһәттән Антанта-Төркия могаһәдәсе ислам дөньясына бер сабак булды, гаять зур бер гыйбрәт булды.

Бүгенге гомуми мөхарәбә нәтиҗәләрендә ислам дошманы булган бөек Русия дәүләте, Русия чарлык истибдады, та әбәд[3] кайтмаслык итеп, ауды, харап булды. Алмания истибдады да инде тәмам ауды, диик. Бу мөляхәза, кабул итик, бәлки тугрыдыр.

---

[1] назар – караш.

[2] тәкъсим – бүлү, бүлгәләү.

[3] та әбәд – мәңгегә.

Башкаларның зарарларында мәнфәгать эзләү сәясәте ислам гыйззәтенә, ислам галәвиятенә мөнасиб[1] булмаса да, минем гакыйдәмә күрә һичкайчан ярый торган эш булмаса да, бүгенге мөхарәбәдән Төркия Дәүләт-и Галиясе истифадә[2] итте; ягъни Төркия Дәүләт Исламиясе куәтле ике дошманыннан котылды, диик.

Ләкин Инглизнең җиһангирлеге сау-сәламәт бөтен куәте белән ялгыз калды. Алмания кебек куәтле, Русия кебек зур ике көндәшеннән Инглиз дәүләте тәмам котылды. Төркия җирләрен, Иран җирләрен яулап алу турындагы хыяллары сугыш башланганчы булсалар да, бүген яулап алу куркынычы тагын да артты.

Куәтле мәдәни дәүләтләрнең көндәшлекләреннән файдаланып яту кебек гаҗизлек[3] сәясәтләренең тәмам хаталыгы бүген тәмам ачык күренде.

Дөрес, Тәүратның, Гаһед гатикъның[4] иң ышанычлы бер бәндәсе, Талмудның[5] иң фәкыйһ[6] шәкерте булган яһүд Карл Маркс кебек бөек бер мөдәббирнең[7] җеннәргә хас бер тәдбире белән әзерләнгән зур куәтле гаскәр,– пролетария гаскәре,– бүгенге сугыш бәрәкәте белән үзләренең өннәреннән чыгып; Ленин кебек куркусыз раһбәрләрнең бөек тәдбирләре белән коралланып; халыкның кулында һәм күңелендә булган кыйммәтле мөкатдәс куәтләрнең һәммәсе агитация куәте белән тәмам тар-мар ителеп; тәкәббер мәгърур империалист дәүләтләрне харап итү гаһеде белән җир йөзендә яңа бер куәт, дәһшәтле бер куәт килеп чыкты.

---

[1] мөнасиб – ятышлы; яраклы; килешеп торучы.

[2] истифадә – файда алу; файдалану.

[3] гаҗиз – көчсез; булдыра алмаучы.

[4] Гаһед Гатикъ – Иске Гаһед (Ветхий завет).

[5] Талмуд – телдән тапшырылган Тәуратны шәрехләү йөзеннән һәм шуның нигезендә барлыкка килгән дини бәхәсләрне үз эченә алган әсәр.

[6] фәкыйһ – шәригать хөкемнәре белгече, шәригать кануннарын булдыручы дин галиме; эшнең яки хәлнең асылын күрүче, зирәк кеше.

[7] мөдәббир – сакчыл; эшләрне оештыручы, җитәкче; тәдбирче.

Лəкин коммунизм гаскəре,– большевиклар гаскəре,– һичбер вакыт төрек дусты, исламият дусты, ислам мəмлəкəтлəренең дусты булмас. Булмаячак. Диннəрнең һəрберенə, мəдəният кануннарының һəрберенə ачык дошман булган коммунизм гаскəре исламият кануннарына, исламның иҗтимагый шəригатенə, төреклəрнең иттихадына[1], ислам миллəтлəренең иттихадына, Хилафəт исламия өметлəренə һичбер вакыт дус булмас, тарафтар булмас.

Иске низамга, иске сəясəткə, диннең иске шəкеллəренə карата халыкның гаять олы нəфрəтлəренə күрə, пролетария куəте мəдəни хөкүмəтлəрнең, мəдəни дəүлəтлəрнең һəрберенə каршы торучы гаять дəһшəтле бер куəт булды, гаять дəһшəтле бер куəт булыр.

Ачлык-ялангачлык, тарлык-юклык кебек кичерə алынмаслык гаять авыр əхвəлнең куəте белəн Русиядə пролетария фетнəлəре, һəрҗирдə һəммə халыкның бөек аякланулары башланды, инсаният дөньясында бөек яңа дəһшəтлəрнең бөтен сəбəплəре тəмам əзерлəнде.

Бүгенге сугышның мөһлик нəтиҗəлəреннəн, əхвəлнең авырлыкларыннан, килəчəк көннəрнең дəһшəтлəреннəн дəүлəтлəрнең һичбере,– зурлары да, кечкенəлəре дə, сугышучылары да, битарафлары да, җиңелгəннəре дə, җиңүчелəре дə – котылмады, котылмас.

Бүгенге икътисади, мəгънəви ифлясларның[2] авырлыклары астында дəүлəтлəрнең һəрбере, хəтта җиңүчелəре дə харап булыр, чыгыш таба алмас.

(مَا تَذَرُ مِن شَيْءٍ أَتَتْ عَلَيْهِ إِلَّا جَعَلَتْهُ كَالرَّمِيمِ)

Мөхарəбə көннəрендə, мөхарəбə нəтиҗəлəрендə, инкыйлаб хəрəкəтлəрендə мəдəният дөньясының тəмам көчсезлеген ачык күрдек. Мəдəният дөньясының һəрьяклап мөфлислеге[3] ачык күренде. Иҗтимагый фикер җиһəте белəн дə, иҗ-

[1] иттихад – бердəмлек; бердəм булу; берлек.

[2] ифляс – бөлгенлек, бөлү; əҗəтне түли алмау.

[3] мөфлис – бөлгенлек.

тимагый низам җиһәте белән дә, инсаннарның[1] саляхларын[2] күрсәтә беләчәк акыл җиһәте белән дә, инсаннарның хокукларын, хөрмәтләрен кабул итә алачак калеб җиһәте белән дә мәдәният дөньясы тәмам мөфлис имеш!

Хикмәтле, дөрес итеп эш йөртүче маһир[3] вә хазикъ[4] мөһәндис[5] мәгърифәте белән төзелгән иҗтимагый бер низам мәдәният дөньясында юк иде, һаман да юк.

Һәммә инсаннарның хокукларын, хөрмәтләрен, хөрриятләрен тәэмин итә алачак бер куәт, бер ихтыяр мәдәният дөньясында юк иде, һаман да юк.

Мәдәният дөньясында, бәлки, бөтен җир йөзендә гомумият яулаган бүгенге сәяси, әхлакый, иҗтимагый, дини гаять бөек бохран фаҗигаләре ифляс җиһәтләрен дә ачык күрсәтте.

Иске хәлләрнең һәрберенә бәдбинлек күзе белән карап; мәдәният низамнарының һәрберен осталык белән көчле тәнкыйтькә дучар итүче, һәм дә үзенең мәһарәтле[6] интикадларында[7] тулысынча дөресен күрсәтүче Карл Маркс – коммунизмның асылларына, коммунизмның истикъбаленә[8] балалар күзе белән багып; буржуйларның һәрберен җәһәннәм чокырларына юллаганнан соң, пролетарияләрнең һәрберенә фирдәвес җәннәтләре турында балаларча беркатлылык белән бәшарәт бирүче Карл Маркс карашында, мәдәният бозыклыкларының, мәдәният хәстәлекләренең баш сәбәбе милек низамы булып, шуның иң файдалы дәвалары, иң тәэсирле гыйлаҗлары[9] революция куәте белән: 1) пролетария диктатурасы, 2) әксәриятнең[10] иҗтимагый хокуктан тәмам мәхрүм

---

[1] инсан – кеше; адәм баласы.

[2] салях – төзеклелек, яхшылык; намуслылык, турылык, яраклылык.

[3] маһир – оста.

[4] хазикъ – бик оста, бик белемле, тәҗрибәле.

[5] мөһәндис – һәндәсә гыйлеме белгече; инженер.

[6] мәһарәт – осталык; уңганлык.

[7] интикад – җитешсезлекләрне күрсәтү, тәнкыйть.

[8] истикъбаль – киләчәк.

[9] гыйлаҗ – әмәл, чара, дару; дәва.

[10] әксәрият – күпчелек.

булуы, 3) милек хокукларыннан тәмам мәхрүм калып, гомуми амбар капкалары янында бөтен инсаннарның һәрҗирдә һәрвакыт гидайлыгы[1], имеш.

Мәдәниятнең бөтен әсәрләре революция куәте белән тәмам җимерелмәдекчә; инсаннарның һәммәсе мәхрүмлек фазыйләтләрендә[2] тәмам бәрабәр булмадыкча; канун урынына, хокук урынына, хөрмәт урынына диктатура куелып, бөтен милләтләр, бөтен шәхесләр һәрьяклап тәмам тәхкыйрь[3] кыйлынмадыкча, һәйәт[4] иҗтимагыя[5] һичбер сурәттә ислях кыйлынмас, имеш.

Бөтен илһамнарын тарихның дәһшәтле хезмәтчеләреннән, мәдәниятнең олы бозыклыкларыннан истифадә иткән Карл Маркс кебек акыл гыйфрите, бер даһи, әлбәттә, бары тик шундый тәдбирләр турында язар.

Тәуратның бәлягате[6] белән, Тәлмуд мәһарәте белән язылган «Капитал»ларын да укыдык; Карл Маркс мәгърифәте белән язылып, коммунист партиясе исеменнән бер вакыт нәшер кыйлынган гаять әһәмиятле «Манифест»ларын да укыдык.

Инсаннарның тарихи әхвәлләренә, рухи әхвәлләренә тәмам вакыйф[7] булып, иске үткәннәрнең бүгенге иҗтимагый хәлләрен бөтен мәһарәт белән интикад итү хосусларында Карл Маркс Тәлмудның иң фәкыйһ шәкертедер, җенле бер гыйфриттер, бөек бер даһидыр. Интикад хосусларында ул һәрвакыт дөресен әйтә.

Ләкин революция гыйфрите – мәдәният хәстәлекләренең табибы була алмый имеш, җәмгыять корылмаларының мөһәндисе дә була алмый, хәят юлларының раһбәре дә була алмый, хәят әдәпләренең хәкиме дә була алмый имеш,– ис-

[1] гидай – хәерче, юксыл; малдан мәхрүм ителгән.

[2] фазыйләт – яхшылык, игелек; өстенлек.

[3] тәхкыйрь – хурлау; мыскыл итү; кимсетү.

[4] һәйәт – комитет, комиссия, коллегия, оешма.

[5] һәйәт иҗтимагыя – җәмгыять төзелеше; иҗтимагый система.

[6] бәлягать – сөйләм һәм язма телнең матурлыгы, төзеклелеге, бәян ителәсе фикерне җиткерүдә камиллеге.

[7] вакыйф – аңлаучы, белүче, эшнең төбенә төшенүче.

ке хәлләрне интикад маһәрәтләрендә дөресен әйткән Карл Маркс,– истикъбаль тәдбирләрен бәян итү хосусларында һәрьяклап хата итте, революция фәлсәфәләрендә даһилек күрсәткән фәйләсүф Карл Маркс иҗтитмагый һәйәт низамнарын ислях кыйлу чараларында бөтенләй зәгыйфь булып чыкты.

Коммунистларның тәуратларын да, «Капитал»ның бөтен җилдләрен[1], бөтен томнарын да укыдык.

Капиталның золымына, тәсхиренә[2] каршы «Капитал»ның беренче җилдендәге кыям[3] дәгъвәтләрен мин дә кабул итәм. Яхшы. Фәлсәфә бәрәкәте белән, диннең иршады[4] белән инкыйлаб чыкмаганнан соң, революция куәте белән инкыйлаб фикерләренә мин дә, әлбәттә, иярә алам. Башка бер чара юк: мөхарәбә нәтиҗәсендә зур форсат чыкканнан соң, әксәриятнең кыямы, әлбәттә, табигый иде; бәлки зарури иде. Русиядә мәшруг[5] чараларның ярдәме белән, әксәриятнең җиңүләре мөхарәбәдән соң тәэмин кыйлына алса да, бу заманда мәшруг чараларның һичбере Русиядә мөмкин түгел иде дә, фетнә революциясе чыкды; яки ихтыяр кыйлынды. Башка бер чара юк иде, диик. Шулай булгандыр, бәлки.

Ләкин һәйәт иҗтимагыя низамнарын хокуктан мәхрум ителү нигезләренә кору, җәмгыять эчендә шәхесләрнең хөрриятләрен, истикъляльләрен тулысынча сәлеб[6] итү, юклык фәлсәфәләреннән иҗимагый бер файда өмет итү, икътисади бәрабәрлекне юклыкта күрү – мондый тәдбирләрнең һичбере инсаннарның сәгадәтләренә, һәйәт иҗтимагыя саляхенә һичбер вакыт хезмәт итмәс.

Коммунистларның инҗилләрен дә укыдык.

---

[1] җилд – күн белән тышланган китап; том.

[2] тәсхир – яулап алу; басып алу.

[3] кыям – күтәрелеш; восстание.

[4] иршад – туры юлга кертү; дөрес юлны күрсәтү; дөрес юнәлеш бирү.

[5] мәшруг – шәригать яки закон тарафыннан карар кылынган; шәригать күзлегеннән дөрес булган.

[6] сәлеб – талап алу.

Агитация каләме белән язылган бәлягатьле кыйсем-е гарызларына[1] күрә [ул инҗилләр] мөфид[2] исә дә, коммунизм фазаларын бәян итү юлында язылган хыяллар кыйсеме гаять зәгыйфь. Инсаннарның халәкатьләренә[3] күрә, андый бер хәят тәмам мөхальдер[4]. Андый бер хәятнең мөмкинлеге бер очракта кабул ителсә, һәрбер инсан, һәрхәлдә, андый бер хәяттән, әлбәттә, бизар[5] булыр, нәфрәт итәр.

Карл Маркс тәгълимнәрен тәфсир юлында Ленин каләме белән язылган «Дәүләт һәм революция» исемле китап, 1919 елда чыккан әүвәлге басмасы моталәга[6] кыйлынса, коммунизм тәгълимнәренең иң зәгыйфь тамырлары тәмам ачык күренер.

Буржуазия әлендә котылмак өчен, дәүләт эчендә революция лязем, имеш; пролетария диктатурасы да лязем вә зарур, имеш, инкыйлаб хосусларында икраһ[7] вә иҗбар[8] гамәлләрен куллану, диктатура хосусларында бөтен халыкның хөрриятләрен вә хокукларын тулысынча сәлеб итү мәшруг, имеш.

Буржуазия дәүләтеннән котылмак өчен, революция зарур булса да, пролетария диктатурасыннан нәҗат юлында революция мәшруг булмаячак, имеш, кирәк булмаячак, имеш. Бәлки пролетария диктатурасы бераз заман дәвам иткәннән соң, ахырда, инкыйраз[9] юлы белән юкка чыгачак, имеш. Пролетария диктатурасы коммунизм шәкеленә әйләнер, имеш.

---

[1] кыйсем-е гарыз – кереш сүз; преамбула.

[2] мөфид – булышлы; файда бирә торган; файдалы.

[3] халәкать – Аллаһ тарафыннан барлыкның булдырылышы, барлыкка китерелүе.

[4] мөхаль – мөмкин булмаган; тормышка аша алмый торган.

[5] бизар – гайрәт чигү; күрәлмау.

[6] моталәга – уку; укып өйрәнү; хөкем чыгару өчен мәсьәләне төрле яктан тикшерү.

[7] икраһ – мәҗбүр итү; ирексезләү; нәрсәне дә булса көчләп эшләтү.

[8] иҗбар – җәберләү, мәҗбүр итү, көчләп ризалату, көчләп эшләтү.

[9] инкыйраз – бетү, юкка чыгу.

Коммунистларның тәгълимнәре, коммунизм китапларының бәяннары будыр!

Йә гарыз юлында дипломатлыктыр, яки хыял сахраларында балалыктыр!

Ике диктатура арасында нәкадәр гаҗәп аерма!

Пролетария диктатурасыннан коммунизм шәкеленә әйләнү вакыйгасында – никадәр сәер бер хадисә, никадәр сәер бер харика[1];

Сезгә дә, безгә дә, әлбәттә, мәгълүм: революция инсанияте дөньясында гаять көһнә[2], тәмам иске бер хәлдер. Гаять көһнә бер коралдыр. Вакыт-вакыт чыга иде. Яки чыгарылыр иде. Ләкин һичбер мәртәбә иң мәхрүм, иң фәкыйрь яки иң мәзълум[3] гомлә[4] тарафыннан булмас иде, булмады, бәлки хәлләре яхшы халык тәдбире белән һәрвакыт үткәрелә иде, башкарыла иде.

Инсаннарның әлләрендә һәрбер нәрсә инсаннарның бозыкларына корал кыйлынды. Хәтта диянәт кебек иң мөкатдәс бер иҗтимагый фазыйләт инсаннарның бозыклыклары өчен корал кыйлынды, хәтта мәдәният кебек иң нафигъ[5] иҗтимагый зарурәт инсаниятнең бозыклыгына корал ителде. «Гомләләрнең, фәкыйрьләрнең әдәпкә кагылышлы хәлләрен ислях» өчен революцияләре дә аристократларның уеннарына, кәеф-сафаларына хезмәт итүче корал ителеп, мәгъсум[6] җаннарны, пакь каннарны аристократларның һаваларына[7] һәрвакыт корбан итә иде; фәкыйрьләрнең, гомләләрнең хәлләрен ислях кыйлу мәшәкатьләреннән, ислях кыйлу тәдбирләреннән һәрвакыт ерак тора иде.

---

[1] харика – гадәттән тыш; искитмәле.

[2] көһнә – иске, борынгы; сәләмә.

[3] мәзълум – изелгән, рәнҗетелгән, кимсетелгән.

[4] гомлә – эшчеләр; эш кешеләре.

[5] нафигъ – файдалы.

[6] мәгъсум – гаепсез ителгән, гөнаһсыз ителгән.

[7] һава – хыяллар; күңел теләге; кәеф; көй (антоним: көйсез; кәефсез).

Без дә, ислам милләтләре дә, революцияләрне беләбез. Үзләре дә, әһәмиятләре дә, вакытына күрә зарурәтләре дә, безгә дә, әлбәттә, мәгълүмдер.

Үзләренең хокукларын, хаҗәтләрен, хөрмәтләрен, шәрәфләрен химая юлында күтәрелеш мәгънәсе белән революция мәшруг нәрсә була алса да, яки зарур була алса да, башкаларның хокукларын, хөрмәтләрен, хөрриятләрен һәдем[1] итмәк, ихтыярларын, хөрриятләрен сәлеб итеп, икраһ итү һичкайчан мәшруг нәрсә булмаячак, файда бирмәячәк. Мөхарәбә сәгатьләрендә иҗтимагый хокукларның вә хөрриятләрнең һәрбере, кабул итик, батыйль[2] булса да, диктатура хокукларның һичберен ибталь[3] итмәс. Халыкның әменнәрен[4], хокукларын тәэмин итүдә зарури тәдбир булса, диктатура мәшруг булыр, тәхәммел[5] кыйлына алыр; файда бирер. Юкса, мәшруг булмас, фәсад[6] булыр, зарар бирер.

Карл Маркс тәгълиме кебек, һәйәт иҗтимагыя каршы торучы ике көч, бер-берсенә дошман булган ике сыйныфтан оешмаган, бәлки берсе белән хезмәттәшлек итүче, берсе икенчесенә ярдәм итүче күпсанлы сыйныфлардан мөәлләфдер.

Агитация куәте белән сыйныфлар арасына дошманлык тарату ислях чарасы була алмый. Бары тик халыкның миләре, күңелләре, гакыйдәләре, фикерләре, әдәп-әхлаклары ислях кыйлынмыйча, революция тәдбирләре фәкыйрьләргә һәм гомләләргә игелек бирмәс, бәрәкәт бирмәс.

Һәрбер дәүләттә, һәрбер һәйәт иҗтимагыядә канун булуы заруридыр, куәт булуы, әлбәттә, зарурдыр. Канун гадел булып, инсаннарның хокукларын, һәр хосусда хөрмәтләрен тулысынча бәрабәр тәэмин итә торган булса; хөкүмәт гаделлекә кануннарын тулысынча үтәп; инсаннарның хаҗәтләренә,

---

[1] һәдем – вату, җимерү, бозу.

[2] батыйль – дөрес түгел, чын түгел; ялганга чыгарылган; буш.

[3] ибталь – юк итү, юкка чыгару; бозыклыгын, ялган булуын күрсәтү.

[4] әмен – куркынычсызлык, иминлек.

[5] тәхәммел – күтәрә алу; түзү, чыдау.

[6] фәсад – бозык, бозыклык; азу, начарлык; начар эш.

кодрәтләренә, кабилиятләренә[1] күрә һәр хосуста ирекле булarak кабул итә торган булса; хөрриятләрен дәүләт куәте белән тәэмин итә торган булса; фәкыйрьләрнең, гомләләрнең хөрмәтләре, хокуклары вә бөтен хаҗәтләре, әлбәттә, тәэмин кыйлыныр.

Һәйәт иҗтимагыянең уку йортларында, күнегүләр башкарыла торган аудиторияләрендә бөек эволюция, куәтле революция профессоры булган карт мөдәббир остаз заман мәгърифәте белән, тарих теле белән, тәҗрибә ысулы белән адәм балаларының игътибарларына сеңдерелеп килгән күнегү дәресләренең катгый холясасы – будыр.

Фәкыйрьләрнең, гомләләрнең мәсълихәтләрен, бәхет-сәгадәтләрен тәэмин итә алырлык бер нигез бары тик будыр. Революция зарур булса да, диктатура зарур булса да, бары тик бу нигезне, яки шундый бер нигезне тәэмин итәр өчен зарур була ала.

Бүгенге мөхарәбәнең нәтиҗәләрен күрдек. Мәдәниятле Гаребнең[2] көчсезлеген дә, аптыравын да тәмам ачык мөшаһәдә[3] иттек. Империалистларның максадларын да, пролетария раһбәрләренең максадларын да тәмам ачык аңладык. Мәдәниятле Гаребнең иҗтимагый фикерләре михрабларында сәҗдә итү түбәнлекләреннән (?)[4], иҗтимагый низамнарына тәкълид[5] итү зилләтләрендән котылдык; Шәрыкъ котылды (?), ләкин мөхарәбә көннәрендә исламият дөньясында гаять бөек бүлгәләнү бәлаләре дәвам итте. Дөрес, бу бүлгәләнү иске хасталыкларның котылгысыз бер нәтиҗәсе иде. Фронтларның һәрберендә үзенең мәсълихәтләренә зарар [килүенә карамастан шулай булды]. Хисабы юк корбаннарын бирде. Форсат дәкыйкалары кулдан ычкынды. Ислам дөньясы икътисад җиһәтеннән дә әүвәлге хәлендә, әүвәлге әсирлегендә калды.

---

[1] кабилийять – сәләтлелек, булдыклылык, эшкә ярау.

[2] Гареб – Көнбатыш.

[3] мөшаһәдә – үз күзең белән күрү, шаһид булу, танык булу.

[4] Сорау билгесе мөхәррир Гаяз Исхакыйныкы.

[5] тәкълид – берәүгә охшашлану; кабатлау; ияру.

Хәтәр артты. Ислам дөньясы ике ут эчендә калды.

Гареб дәүләтләрен дә зур хастаханә хәленә китергән Версаль-Сәвер могаһәдәләренең шартлары, нигезләре, гомуми инкыйлабның күренешләре, юллары – ислам дөньясының олы өметләренә тулысынча каршы килгән хәлләрне, мөкатдәс гакыйдәләренә тәмам каршы килгән мәсьәләләрне иҗтимагый яшәеш сыйныфларына чыгарды.

Олы бәрәкәтле ислам җирләре бөек дәүләтләрнең куәтле хирысларына һәдәф[1] иде. Инкыйлабтан соң бүгенге сәяси көрәшләрдә бөек куәтле ике дошманның бәрелешләренә ислам җирләре элеккеге кебек мая булып, алар тарафыннан басып алынуның һәдәфе булып калды. Ислам мәмләкәтләренең мәдәни дәүләтләргә нисбәтән вазгыятьләре һаман әүвәлге хәлендә калды.

Һәдәфлек зилләтләреннән чыгып, хак вә хокук иясе булу, мөстәкыйль бер тараф булу дәкыйкаларыдыр бүген!

Безгә канәгать бирә алачак максат бары тик будыр. Ике тарафның һичбере безнең бу максатыбызны безгә тәэмин итмәс. Бары ялңыз[2] ислам куәте, ялңыз төрек иманы тәэмин итәр.

Исламият шәрәфенә нәҗат таңы төрек куәте белән атты, истикъляль көне якынлашты.

Бүгенге инкыйлабның туфаннары, дулкыннары арасында тәмам хәрап ителгән мәдәният хәрабәләре эчендә, Версаль-Сәвер могаһәдәләренең мөһлик сихере белән зәһәрләнеп мәҗнүн[3] кебек булган мәдәни дәүләтләрнең хәрәкәтләрендә, аптырап-югалып калуларында хозурында үзен гаъиб итмәмеш[4] нәҗиб ислами төрек милләтенең ныклыгында, күргән чараларында нәҗатебезнең галәмәтләрен күрдек, нәҗатебез бәшарәтләрен ишеттек.

Царизм, Инглиз, Фирансия, Америка сәясәтләре безгә бөтен серләре белән ачык мәгълүм иде. Инкыйлаб хәрәкәтлә-

---

[1] һәдәф – үзенә төбәлеп атылырга тиешле нәрсә; төбәлү ноктасы, мишень.

[2] ялңыз – тик, бары тик.

[3] мәҗнүн – җенле, җенләнгән.

[4] гаъиб итмәмеш – югалтмамыш, югалтмаган.

ренең, инкыйлаб юлларының шәкелләре дә истикъбалебезне безгә ачык мәгълүм итте. Партия програмнарының гамәлдә үтәлеше дә ислам тәгълиматына мәхәббәтебезне тәэкид[1] итде.

Ислам дөньясы моннан соң ялңыз ислам дөньясына таяначак. Төркия ислам мәмләкәтләренең һәрберенә нәмунә[2] булып раһбәр булыр, имам булыр.

Икътисади вә сәяси әсирлектән ислам дөньясының нәҗате дә ялңыз үзенең кулында, үзенең куәте белән була алыр. Булыр. (إِنَّ نَصْرَ اللّٰهِ قَرِيبٌ)[3].

Ислам җирләре үзенең бәрәкәтле мәхсуляте[4] белән әһле исламны тәрбия итәр, әлбәттә. Дахили[5] фетнәләрдән азат калыр, әлбәттә. Гаять зур бу ике хосусыятьнең бәрәкәте белән ислам мәмләкәтләренең нәҗатләре, истикъбальләре, әлбәттә, тәэмин кыйлыныр, иншә Аллаһ.

Ислам үзенең мөкатдәс Коръәне белән, үзенең һәрнәрсәне сыйдырган иҗтимагый шәригате белән мөстәгъни[6] булыр, әлбәттә, башкаларның тәүратларына, капиталларына, партияләрнең програмнарына мохтаҗ булмас, әлбәттә. Йогышлы һәрбер чирнең бер дафигасе[7], бер тәлкыйхы[8] бар, булмаса – табылыр. Тагун[9] кебек йогышлы революция фетнәләренә дә ислам иманы, ислам әманәте[10], ислам тәгълимнәре каршы тора алачак.

---

[1] тәэкид – раслау, куәтләү, ныгыту.

[2] нәмунә – үрнәк, өлге.

[3] «Чынлыкта, Аллаһның ярдәме бик якын» (Коръән, 2:214).

[4] мәхсулат – барлыкка килгән әйбер, табигый байлыклар, җирдән алынган уңыш.

[5] дәхили – эчке; илнең эчке вазгыятенә бәйле.

[6] мөстәгъни – хаҗәт кичерми торган, кемнең дә булса ярдәменә мохтаҗ булмаган.

[7] дафига – нәрсәгә булса да каршылык күрсәтүче, каршы торучы нәрсә.

[8] тәлкыйх – организмның теге яки бу авыруга каршы торырга әзер булуы өчен каралган чара, вакцинация.

[9] тагун – тагун чире; чума.

[10] әманәт – турылыклылык, ышанычлылык; гарантия.

Ислам җирләрендә икътисади революция чыкмаячак. Революция гамилләренә[1] ислам мәмләкәтләренең ихтыяҗы да юк.

Ләкин төпле бер шәкелдә әдәби[2] вә иҗтимагый инкыйлаб ислам мәмләкәтләрендә, әлбәттә, башланачак. Куәтле нигезле бер инкыйлаб ислам мәмләкәтләренең һәрберенә бүген, әлбәттә, зарурдыр.

Һәммә милләтләрдән күбрәк корбан биреп тә, бөтен ганимәтләрдән тәмам мәхрүм калган булсак та, бу гомуми мөхарәбәнең тәэсире белән, бүгенге инкыйлаб бәрәкәте белән әдәби инкыйлаб ганимәте ислам милләтләренең өлешенә калыр, иншә Аллаһ.

Әдәби инкыйлабның мөҗиз[3] бер әбҗәде[4], нык бер нигезе буларак, әлеге «Исламият әлифбасы» әһле исламның олы игътибарларына тәкъдим кыйлынды.

Иң зур дәүләтләрне дә җир йөзеннән тәмам сызып аткан, тулысынча себереп юкка чыгарган, һәм дә иң бай, иң куәтле дәүләтләрне дә тәмам гаҗиз иткән бүгенге гомуми мөхарәбәдә гаять зур, гаять көчле каһарманлык күрсәтеп, Чанак кальгасында бөтен дөнья куәтләрен һәм бәхрияләрен җиңгән һәм дә үзен югалтмаган шанлы төрек гаскәре шәрәфенә сәяси нәҗат, әдәби инкыйлаб хосусларында бөтен әһле исламның раһбәре булачак төрек милләт нәҗибәсенең олы хөрмәтенә атап кулыгыздагы бу «Исламият әлифбасы» язылды.

Шанлы төрек гаскәре шәрәфенә бу «Әлифба»мны нәшер иттем. Бер максатым бар иде: партияләрнең гаять куәтле агитацияләре сыйнфый дошманлыкны гомүмнең күңелләренә сеңдергән чакта, яшәеш әдәпләре, яшәеш ысуллары турында ислам теле белән сөйләдем, Коръән кәримнең күрсәтмәләрен мөэминнәрнең һәрберенә ирештердем.

---

[1] гамил – эшче, эшләүче; эш башкаручы, хезмәт иясе.

[2] әдәби – әдәпкә, әдәп мәсьәләләренә караган.

[3] мөҗиз – кыска; кыскартылган, кыска рәвештә бирелгән.

[4] әбҗәд – гарәп әлифбасындагы хәрефләр аша цифра һәм саннарны бирү өчен кулланыла торган ясалма кыскартмаларның беренче сүзе; биредә конспект мәгънәсендә кулланыла.

Гомуми мөхарәбә бүген тукталды исә дә, гаять чиркандыргыч могаһәдәләренең, гаять олы тәкәбберләнүләренең тәэсире белән, бәррия-бәхрия хәрби куәтләрендә өстенлек өчен ярышулары зур дәүләтләр арасында гаять җитди сурәттә башланып, якын елларның берсендә әүвәлгедән дә дәһшәтле мөхарәбәләрнең кабынып китүе ихтималдыр. Бу, бәлки, котылгысыз булыр.

Ул чакта ислам мәмләкәтләре дә әзер булып, сугыш маясы, орыш максаты булудан туктар. Киресенчә, сахиб-е хак булыр. Ул чакта ислам дәүләт галияләре, ягъни Төркия, Иран, Әфганстан вә башкалар үзләренең гыйззәтләрен, хөрмәтле булуларын тәэмин итәрләр. Бүгенге Гареб мәдәниятеннән ислам дөньясы бүген файдаланып, әдәби инкыйлаб бәрәкәте белән ислам мәмләкәтләре ул чакта зур бер куәт тәшкил итеп, инсаният мәсълихәтләрен тәэмин итәчәк исламият ул чакта җиңүче булыр, газиз булыр.

(كَتَبَ اللَّهُ لَأَغْلِبَنَّ أَنَا وَرُسُلِي إِنَّ اللَّهَ قَوِيٌّ عَزِيزٌ)[1]

*1921 сәнә, март 28 да, Ташкәнд, Йуныс Хан мәдрәсәсендә*

*Пролетариянең дусты: Муса Җаруллаһ*

Бу китапның бу юллары, бу сәхифәләре, һәм дә бу китапның бөтен маддәләре Русиядә иң авыр әхвәл эчендә, Русия мөселманнарының бөтен дөньядан тәмам киселеп атылган дәкыйкасендә, 1920 ел урталарында язылып; 1920 ел сентябрьнең 16–28-сендә үткәрелгән нәдвәсендә[2], ислам руханиларының бөек корылтаенда укылган иде. Төркестан, Әфганстан, Төркия, Финляндия матбагаларының берендә табыг иттереп, ислам мәмләкәтләрендә тарату арзусы юлында тырышсам да, мөвәффәкъ[3] була алмадым.

Бу өч-дүрт ел эчендә, Төркия гаскәренең хәреб мәйданнарында, Бөек Милләт Мәҗлесенең сәясәт мәйданнарында

---

[1] «Аллаһ: «Әлбәттә, Мин җиңәчәкмен, һәм минем илчеләрем!» дип теркәп куйды, чөнки, чынлыкта, Аллаһ куәтле вә гыйззәтледер» (Коран, 58:21).

[2] нәдвә – җыен; җыелыш; киңәшмә; корылтай.

[3] мөвәффәкъ – уңышлы булу; бәхетле булу.

бөек мөвәффәкыятьләре бу сәхифәләрдәге минем өметләремне ачык аклады.

1919 сәнә[1] сентябрь-июль айларында, бере Эрзурумда, бере Сивасда тупланган Хокук миллия җәмгыятьләренең бөек корылтайларында кабул кыйлып, 1920 сәнә гыйнуар 28-дә, Истанбул Мәҗлес-е Мәбгусаны тарафыннан да кабул кыйлынган алты маддәлек Мисак-ы Милли нөсхәсе безгә дә иреште. Олы бер шатлык белән укыдык, истифадә иттек.

Мисак-ы Милли – төрекләрнең садакатьле лисаны белән, куәтле иманы белән тәэкид кыйлынган бер анттыр, бөтен милләтләргә бирелгән мөкатдәс бер гаһедтер, мәдәни милләтләргә игълан кыйлынган әһәмиятле сәяси бер документтыр, куәтле гыйззәтле милләтнең кямил иманына гүзәл бер күрсәткечтер, бөек милләтнең шәрәфле газаматына гаять җалиб бер нәмунәдер, Төркиядәге милли хәрәкәтләрнең какшамас бер нигезедер, хикмәтле бер раһбәредер.

1919–1920 сәнәләрдәге дәһшәтле әхвәл эчендә, чит ил куәтләренең Төркия җиренә истиляләре дәкыйкаларында, Сәвер могаһәдәсенең иртәгесе көнендә Төркия вилаятьләренең Антанта дәүләтләре арасында кисәкләргә бүленүләре Гарәфәсендә[2] булулары тәэсире белән булса кирәк, Мисак-ы Милли маддәләре «фидакярлекнең хәдд-е әгъзамиләрене[3] мөтәзамин[4] әсасәтне»[5] бәян итү юлында мәҗбүрилек лисаны белән язылып; Төркия кебек Хилафәт исламия сахибы[6] булган мөстәкыйль бер дәүләтнең аңа тиешле һәм мөмкин булган хокукларын, милли куәтләр, хәрәкәтләрнең ахыр чиктәге максатларын игълан итү юлында, тәгайенләү юлында язылган.

---

[1] сәнә – ел.

[2] Гарафә – Гарәфә тавы. Язмышның хәлиткеч борылышы, хөкем ителү мәгънәсендә.

[3] хәдд әгъзами – олуглыкның мөмкин булган иң соңгы ноктасы, чиге.

[4] мөтәзаммин – үз эченә алучы; колачлаучы.

[5] фидакярлекнең хәдд-е әгъзамиләрене мөтәзамин әсасәте – үз эченә фидакярлекнең иң олуг чикләрен алган нигезләр.

[6] сахиб – ия; хуҗа.

Дөрес, хаклы һәм дәвамлы бер солыхның тәэмин кыйлынуы бүгенге көндә, әлбәттә, зарурдыр. Ләкин «хаклы, дәвамлы бер солыхка ирешү юлында сайланыла алачак фидакярлекнең иң югары чикләре» Версаль-Сәвер могаһәдәләрен язган хирыслы дипломатларның ач күзләренең упкыннарын тулдырмаячак; кече күңеллелек күрсәтер кадәр түбәнчелекле булуыгызның кадерен белмәячәк, бәлки үзсүзлелекләренә, олылануларына юл ачачак.

Дөрес, «искә алынган нигезләрдән читтә калып, нык бер госманлы дәүләтнең бар булуы мөмкин түгел». (?) Ләкин «фидакярлекнең иң югары чикләре эчендә» аякларында нык торучы Төркия дәүләте дә була алмаячак, дәвам итмәячәк.

Минем сурәтләвемчә, моннан соң мәдәниятле булачак Төркия дәүләте икътисад дөньясында мөһим бер гамил булыр; исламият дөньясында акыллы бер раһбәр булыр; ислам милләтләренә, ислам дәүләтләренә имам була алачак бер хилафәт булыр. Мондый сурәтләү, мондый арзу әһле исламның һәрберендә, әлбәттә, бар.

Төркия Бөек Милләт Мәҗлесе бөек Хилафәт исламиянең сахибы булып, ислам дәүләтләре, ислам милләтләре назарында Төркия Дәүләт-и Галиясенең хөрмәте Хилафәт куәте белән тәэмин кыйлына башламыйча; ислам дәүләтләренең уртак милке булган Мөкаддәс Хәрәмне – Гарәбстан ярымутравын мөхтәрәм бер ислам мәмләкәте кыйлып, Хилафәт исламия кулында булмыйча; Сүрия кебек, Мисыр кебек, Хиҗаз кебек Төркия Дәүләт-и Галиясенең элеккеге вилаятьләре үзләренең кямил ихтыярларына ирешеп, Хилафәт исламия җамигасендә[1] мөстәкыйль бер мәмләкәт булмыйча; Гареб мәмләкәтләрен истиля иткән ихтиляль туфаннары Төркия җиреннән кубарып атылып, ислам пролетарияләренең икътисади хокуклары Коръән кәримнең гаделлеге белән тәэмин кыйлынмыйча; Төркия Дәүләт-и Галия Исламиясе моннан соң аякта кала алмаячак.

Төркия җирендә калачак һәр милли азчылыкның хокукы, хөрмәте, хөррияте Милли мисакның 5нче маддәсендә

[1] җамига – җәмгыять; берләшмә, оешма.

шулкадәр ачыклык белән тәэмин ителеп ышандырылганнан соң да, мәдәни дәүләтләрендәге мөселман күпчелекләре хакында ни бер хәреф, ни бер сүз язмау, бары тик «күрше мәмләкәтләрдәге мөселманнарның шундый ук хокукларга ия булулары» турында бердән бер «әмния[1]» сүзен язып кую кебек беркатлылык нидән иде?

Мөтәрәкә[2] Мисак миллидән алда каралган иде. Мисак милли маддәләре дә мөтәрәкә карарларыннан котылу дәгъвасы белән булды. Алайса, Төркия җирен гарәп күпчелеге яшәгән, госманлы ислам[3] күпчелеге яшәгән кисәкләргә тәкъсим итеп, мөтәрәкә чикләрен игътибарга алган кебек бүлү; һәм дә «хакыйкатьтә йә хөкемдә һичбер сәбәп белән аерылуны кабул итмәс бер бөтенлек» булачак Төркия җирен мөтәрәкә чикләре эченә кертеп хасыр[4] итмәк мәҗбүрияте нидән иде?

Дөрес, гомумиятнең карашларына мөрәҗәгать итү кебек кануни гадәт һәр милләт хакында хаклы нәрсә булса да, үзләренең хосусый гарәп әхвәлләрендә гарәп күпчелеге дә үзләренең ихтыярларында кала ала. Ләкин, Ике Хәрәм җәзирәсе[5] булган Гарәпстан кебек бәйнәлислам[6] булып калачак бер ислами кыйтга Хилафәт исламиядән, ягъни Төркиядән тәмам киселеп атылган бер гарәби кыйтга булып кала алмаячак. Бөтен ислам кыйбласы булып калачак Хәрәмәйн[7] җәзирәсенең сәяси-иҗтимагый кыйммәте ялңыз гомумгарәпнең карашлары белән тәгайен кыйлына алмый. Ислам кыйтгасында бөтен әһле исламның хакы бәрабәрдер. Истанбулның һәр зыяннан, хәтта һәр андый ихтималдан мәсунияте[8] никадәр мөһим бул-

[1] әмния – ышандырып кую; гарантия.

[2] мөтәрәкә – сугышны туктатып тору турындагы килешү, вакытлы солых.

[3] госманлы ислам – госманлы мөселманнар, ягъни төрекләр.

[4] хасыр – урап алу, камап алу; чикләү; бикләп кую, кысрыклау.

[5] җәзирә – утрау; төбәк.

[6] бәйнәлислам – исламара, ягъни бөтен мөселманнарныкы булган.

[7] Хәрәмәйн – Ике хәрәм, ягъни Ике тыюлык (Мәккә белән Мәдинәдәге изге урыннарның гомумиләштерелгән атамасы.

[8] мәсуният – сакланганлык; иминлеклелек.

са, Хилафәт исламия кулында Мәккә-Мәдинә җәзирәсенең дә шулкадәр, бәлки, аннан да артык мәсунияте, тагын да артык төзек булуы, җитешле булуы күпкә мөһимрәк. Бугазларның бөтен дөнья тиҗарәтләренә[1], мөнакалятенә[2] ачыклыгы никадәр әһәмиятле исә, хилафәт исламия кулында калып Мәккә-Мәдинә җәзирәсенең бөтен дөнья мөселманнарына һәрвакыт ачыклыгы да шукадәр мөһимдер.

«Шартлар тәртипкә китерелүе дәүләтнең истикъляленә, тулы хөрриятенә, милләтнең сәяси-икътисади инкишафына[3] киртә булмаса, дөреслеге расланган бурычларның һәммәсе тулысы белән түләнәчәк»,– дигән мәгънәдә булган иң соң җөмләсе – Милли мисакның гаять әһәмиятле бер маддәседер. Андагы гаять бөек әманәтләренең нәмунәседер. Төреклек исеменә, ислам диненә олы бер шәрәфтер.
(فَلَكُمْ رُؤُوسُ أَمْوَالِكُمْ لاَ تَظْلِمُونَ وَلاَ تُظْلَمُونَ وَإِن كَانَ ذُو عُسْرَةٍ فَنَظِرَةٌ إِلَى مَيْسَرَةٍ).

Мисак милли маддәләренә кагылышлы бу мөляхазәләремне яздым. Интикад кыйлу хыялы белән түгел иде. Аларның язылуы тарихы минем хәтеремдәдер. Сәвер могаһәдәсенең иртәгесе көнендә Төркия җиренә истиля иткән дәһшәтле әхвәлнең, кимендә, миллионнан бере безнең Русия җирендә дә бар иде. Мөляхазәләрым гафиллеккә нигезләнгән тәнкыйть була алмый.

Минем бу мөляхазаларым – Төркия хилафәт исламиясе хакында ислам милләтләренең гакыйдәләрен, назарларын, өметләрен дөрес сурәттә бер аңлатып бирүдер. Сугыш кырларында Төрек гаскәренең җиңүләре, сәясәт сәхнәләрендә, сәяси уеннарда төрек раһбәрләренең мәһарәтләре Төркия хилафәт исламиясе хакында ислам милләтләренең гакыйдәләрен тасдикъ[4] итә[р өчен] яздым. Минем өметләрем якын көннәрдә тулысынча тәхкыйк[5] кыйлынып, Төркия хилафәт исламиясе һәм дини, һәм сәяси, һәм икътисади инкишафлар

[1] тиҗарәт – сәүдә; алыш-биреш.

[2] мөнакалят – сәүдә өчен туар (товар) күчереп йөртү.

[3] инкишаф – ачылу, мәйданга чыгу.

[4] тасдикъ – раслау, дөрес дип әйтү, дөреслеген тану.

[5] тәхкыйк – хакыйкатькә әйләнү.

юлларында бөтен ислам милләтләренә һәм нәмунә булыр, һәм раһбәр булыр. Ислам милләтләренең һәрбере Төркия хилафәт исламиясенә икътида[1] итеп, үз куәте белән, үз иманы белән, үз ихтыяры белән диянәт һәм мәдәният юлларында мөсабәка[2] итәр.

*Муса Җаруллаһ*

*Петроград. 1923 сәнә февраль җидедә.*

---

[1] икътида – охшашлану; иярү.

[2] мөсабәка – ярышу.

## «Заключение»[1]

По делу № 21140 по обвинению гр-на Бигиева Джарулла, 52 лет, по национальности татарина, окончившего ряд высших мусульманских учебных заведений как в России, так и за границей, муллы гор. Петрограда

1924 г. января 16 дня я, Нач. II-го Отделения ВООГПУ, Дьяков Таричан, рассмотрев дело по обвинению гр-на МУСА ДЖАРУЛЛА БИГИЕВА в ряде преступлений контр-революционного характера и деяний, направленных против порядка управления, установленного в Союзе Соц. Сов. Республик, выразившихся как в непосредственной связи обвиняемого Муса БИГИЕВА с Турецким послом в Москве, так и в его трудах, направленных против законоположений установленных в Союзе, преследуемых согласно ст. ст. 59,70,72,75 /часть I/, 76 /часть II/ и 84 /часть I/, Уголовного кодекса, Н А Ш Е Л:

Дело возникло согласно ряда получаемых в ВООГПУ материалов, указывающих на БИГИЕВА, как на одного из виднейших идеологов панисламизма /Иттихадистов/, связанного с турецким посольством и направляющего свою деятельность против Соввласти. Последние материалы, говорили. С одной стороны, о стремлении М.БИГИЕВА выехать в Калькутта /Индия/ для участия на всемусульманском с’езде и, с другой – на издание им в Берлине книги, в которой БИГИЕВ явно старается показать всему мусульманскому миру неприемлемость для мусульман Соввласти.

Дальнейшая разработка дела ПОКАЗАЛА:

---

[1] Чыганак: ЦА ФСБ РФ. Архивно-следственное дело № Р-46032. (Документның орфографиясе һәм башка үзенчәлекләре чыганактагы хәлендә китерелә).

I/ В ОБЛАСТИ СВЯЗИ БИГИЕВА С ТУРЕЦКИМ ПОСОЛЬСТВОМ В МОСКВЕ И ОТДЕЛЬНЫМИ ПОЛИТИЧЕСКИМИ ДЕЯТЕЛЯМИ МУСУЛЬМАНАМИ.

I/ Агентурная разработка бела показала, что БИГИЕВ Муса неоднакратно видился и поддерживал связь с турецким послом в Москве МУХТАР БЕЕМ. Тем же путем было установлено, что БИГИЕВ чрезвычайно интересуется всеми более – менее видными турецкими политическими деятелями, приезжающими в Совроссию.

В порядке следственной разработки было выяснено что БИГИЕВ действительно часто встречался с Мухтар Беем и другими, ранее бывшими в Москве турецкими деятелями. В своих показаниях Бигиев говорит, что он, как мусульманский ученый, строгий последователь учения Магомета и приверженец Халифата естественно интересовался событиями в Турции и пользовался всеми возможностями услышать о том, что делается в Турецком государстве.

Считая себя одним из виднейших идеологов панисламизма, МУСА БИГИЕВ, зная, что каждый турецкий представитель, каждый общественный деятель Турции безусловно не откажется от свидания с ним. Не имея возможности получать регулярно турецкие периодические издания с 1914 г., Муса Бигиев, по его показаниям, и пользовался своей известностью мусульманского писателя для получения о Турции информации непосредственно от самих турок.

С другой стороны, как мусульманскому ученому, ему было чрезвычайно интересно ознакомиться с взглядами турецких деятелей на политическую ситуацию в данный момент и на применение основ учения корана в современной политике Турции, как носительнице Халифата.

Таком образом БИГИЕВ показал, что его свидания с представителями Турции имели следующие цели:

1/ Получение информации о Турции.

2/ Ознакомление с идеологией видных турецких деятелей как представителей мусульманского мира.–

В подтверждение последнего БИГИЕВ приводит целый ряд индусских мусульман во главе с проф. БАРАКАТУЛЛОЙ, с которыми от также неоднакратно встречался именно с целью установления известной общемусульманской идеологии в современных условиях.–

БИГИЕВ имел свидания после революции в ЭНВЕР ПАШЕЙ, БЕНР САМИ, ДЖЕМАЛЬ ПАШЕЙ, АЛИ-ПАШЕЙ, МУХТАР-БЕЕМ СУБХИ, и др. и до революции с МАХМУД АСАД ЭФФЕНДИ, ХУССЕЙН ХИЛЬМИ и др.

Большинство свиданий происходило в Москве, с Субхи же Бигиев виделся в Туркестане. Там же он мельком познакомился и с СЕЛИМ ПАШЕЙ /САМИ бей/ на которого не обратил особого внимания, считая его рядовым деятелем.–

3/ Там же БИГИЕВ имел свидания с Афганскими представителями: ВАЛИ МУХАМЕД ханом /теперь министр иностранных дел Афганистана/, МИРЗА МУХАМЕД ХАНОМ, ГУЛЯМ НАБИ /посол в Москве/ и рядом других афганских ученых и политических деятелей. Свидания носили частный характер, причем основной темой бесед являлись вопросы религии.

4/ В своих показаниях Муса Бигиев неоднакратно указывает на тесную идеологическую связь между ним и Бaракатуллой. Через последнего Бигиев познакомился с некоторыми мусульманскими деятелями из Индии. Общей точкой соприкосновения и в данном случае являлись вопросы религиозного характера.

II. Книга БИГИЕВА «О духовно-моральных и социально-политических вопросах и задачах» и обращение его к Вел. Нац.собранию Турции.–

Вполне характеризующим деятельность и сокровенные мысли Бигиева, является его последний труд: «мусульманским нациям о духовно моральных и социально политических вопросах и задачах».

Этот труд был написан Бигиевым по его показаниям в 1920 году, но появился в печати лишь в конце 1923 г.

Из послесловия к книге видно, что она давно была разослана в типографии мусульманских государств и окраин для печатания, но лиш в прошлом году была издана на средства финляндских мусульман. Из показаний же Бигиева следует, что он еще раньше /в 20 году/ давал ее на прочтение некоторым мусульманам и, что корректировал этот труд известный татарский деятель, бежавший от Соввласти ГАЯЗ ИСХАКОВ.

Основными вопросами, разбираемыми Бигиевым в его труде являются:

а/ Отношение мусульманского мира к Соввласти /в частности Турции/.

б/ Халифат, обязанности по отношению к нему мусульманского мира. /Турции с другими мусгосударствами/.

в/ Отношение мусульман союза к Соввласти.

Уже по этим основным моментам видно, что книга является ни чем иным, как попыткой создать политическую азбуку для мусульман. Так и понимает свой труд сам Бигиев, в своих показаниях заявляющий, что он хотел этой книгой показать, каковы должны быть политические воззрения каждого мусульманина, какая тактика по отношению к Соввласти вытекает из Корана.

Начиная с введения и кончая послесловием, книга проникнута нескрываемой ненавистью к принципам Советского строительства.

На первый вопрос Муса Бигиев в своей книге отвечает по существу так: Соввласть бросила лозунги освобождения порабощенных национальностей от гнета империализма, но как только столкнулась с практическим проведением на Востокраинах этого принципа, фактически закабалила мусульман живущих в пределах РСФСР ничуть не менее чем Англия свои колонии.

Наряду с этим БИГИЕВ, считает, что халифат, представителем которого является Турция, должен являться высшей властью в политическом отношении.

Сопоставляя оба положения Бигиев договаривается до призыва /правда не в очень резкой форме/ к мусульманскому

населению Союза к отказу от мобилизации в случае войны с Турцией.

Всю выручку от продажи своей книги БИГИЕВ хотел пожертвовать в пользу детей турецких солдат убитых во время империалистической войны.

Желая издать книгу в Турции Бигиев связался с Субхи, приезжавшим в Совроссию в 1920–1921 гг. Бигиев поручил Субхи передать В.Н.С.Т. обращение, в коем высказывая свои взгляды на современное положение Турции, в частности особенно внимательно разбирает вопросы об отношении мусульман к Соввласти. Здесь Бигиев еще резче, чем в своей книге, нападает на Соввласть, переходя зачастую от нападок к прямым указаниям на то, что РСФСР более опасный враг для мусульманского мира чем Англия.

Это обращение, по словам БИГИВА, он хотел направить в ВНСТ в качестве раз'яснения к своей книге «мусульманским нациям».

III. Связь Бигиева с мус. нац. движением на востокраинах.

Если связь с мусульманскими деятелями Турции была для М. Бигиева единственным источником получения информации о мусульманском мире, то связь его с мусульманами союза, имела характер идеологической спайки.

Еще в порядке агентурной разработки дела была выявлена постоянная связь, существующая у Бигиева со всеми видными деятелями пантюркизма и мусдуховенства Союза. Больше того связь Бигиева не ограничивалась деятелями татарскими и башкирскими, распространялась и на националистов Туркестана и Бухары. Так например, уже при ведении следствия у Бигиева были обнаружены записи целого ряда фамилий мулл Татарии, Сибири и Туркестана, наряду с которыми встречались имена ФАЙЗУЛЛЫ ХОДЖАЕВА, АБДУРАШИДОВА и т.д.

Дальнейшие показания Бигиева по этому вопросу сводились: I/ к полнейшему отрицанию какой-либо практической работы «Иттихад-Ислама» на территории союза, причем Бигиев утверждал, то единственным иттихадистом в Союзе

является он. 2/ об'ясняя свои связи Бигиев всячески подчеркивал, что он являясь одним из виднейших мусульманских писателей во всем мире, имеет целый ряд учеников, т.е. лиц советывающихся с ним по религиозным вопросам и 3/ к желанию всячески доказать невозможность каких бы то ни было организаций или группировок среди мусульман, направленных против Соввласти.

Между тем агентурные материалы подтверждались все время, а они указывали на то, что Бигиев являлся безусловно идеологом всех пантюркистских и панисламистских течений существующих в Союзе. Дальнейший материал показал, что действительно многие практические деятели, являясь учениками Бигиева по своей идеологии все же не посвящали, очевидно, его в свою повседневную работу, считая Бигиева абсолютно не способным к практической деятельности. Таким образом сопоставляя имеющиеся материалы с показаниями Бигиева следует считать, что он безусловно являясь одним из самых видных представителей тат. националистов, несмотря на свою связь со всеми антисоветскими группировками мусульманского мира, в частности с эмиграцией, все же оставался в стороне от практической работы этих группировок и представлял собою лишь борца на идеологическом фронте.

Также не подлежит ни малейшему сомнению, что Бигиев все же знает больше чем дает в своих показаниях, но будучи связан своими убеждениями считает невозможным некоторые известные ему факты передать в показаниях.

В процессе следствия Бигиев отказывается от большей части своих взглядов на Совправительство, как врага мусульман, отстаивая все же основные моменты своего учения /халифат, необходимость свободы вероучения и т.д./. Несколько попыток оправдать свои резкие нападки на Соввласть в разбираемом труде Бигиев строит на неправильном понимании его книги, но в результате все же признает в последнем своем опросе неправильность своих взглядов, что следует считать признанием к-рев. смысла своего учения.

Резюмируя сказанное видно, что Муса Бигиев безусловно виновен:

1/ В стремлении путем распространения своего труда подорвать престиж Соввласти среди мусульман.

2/ В идеологической связи с мусульманскими контр-революционными группировками и

3/ В связи с турецкими общественными деятелями и в частности с турецким послом в Москве.

Принимая же во внимание частичное раскаяние БИГИЕВА и заверения его в из'ятии своей книги «Мусульманским нациям» с рынка, а также нежелательность применения к Бигиеву репрессивных мер в силу его популярности среди муснаселения, П О Л А Г А Ю:

1/ БИГИЕВА Муса Джарулла из под стражи освободить, лишив его права проживания в Петрограде и его окрестностях, выселив его в г. Москву.

2/ Дело прекратить и сдать в архив.

СПРАВКА: Арестованный БИГЕЕВ Муса Джарулла содержится во внутренней тюрьме ОГПУ.

НАЧ. II-го ОТДЕЛЕНИЯ ВООГПУ _______ /Дьяков/

УТВЕРЖДАЮ: НАЧ.ВООГПУ ________/Петерс/

## «Мөскират» китабыннан: Сүз бисмилласы[1]

1925 елда октябрьнең алтысыннан ноябрьнең унсигезләренә кадәр, Кырымда үткәргән ялым һәм сәяхәтем вакытында, һәр җирдә һәм һәр көн булып торган мәҗлесләрнең, әңгәмә-сөхбәтләрнең һәрберендә һәм җәмәгатьчелек тарафыннан, һәм Кырымның мөхтәрәм имамнары, мөхтәрәм хатыйб әфәнделәре тарафыннан гайәт олы кызыксыну белән аракы мәсьәләләре, шәраб мәсьәләләре бәхәс үзәгенә куела иде.

Аракы-шәраб мәсьәләләренә һәм җәмәгатьчелекнең, һәм мөхтәрәм имам-хатыйб әфәнделәрнең ни сәбәптән бу кадәр гадәттән тыш игътибар итүләрен мин аңламый идем. Бу хәлгә хәтта бераз аптырап карадым, хәтта сәерсенеп тә калдым.

Мәҗлесләрдә катнашкан бөтен җәмәгатьчелекнең дә, мөхтәрәм имам әфәнделәрнең истифталары[2] гайәт олы ихтирам белдергән тел белән, сүз белән яңгыратыла иде. Ул мәҗлесләрдәге фикер алышуларда гайәт югары әдәплелек ригая кыйлына иде[3]. Бөек инкыйлаб[4] хәрәкәтләре эчендә калган хәлдә дә җәмәгатьчелекнең, халыкның диннәренә карата, дини мәсьәләләргә карата белдергән бу кадәр зур ихтирамнары мине сөендерә иде.

---

[1] Чыганак: Җаруллаһ, Муса. Шәригать исламийә назарында мөскират мәсьәләләре. Истанбул: Мәхмәд бәк матбагасы, 1927. Б. 3–6. (Өзек татар теленә тәрҗемә ителде).

[2] истифта – фәтва эстәү, ягъни нинди дә булса мәсьәләгә карата шәргый җавап бирелүен, шәригатькә туры килгән карар бирелүен, фәтва чыгарылуын таләп итеп шәригать белгеченә мөрәҗәгать итү.

[3] ригая кыйлына иде – кайгыртыла иде, саклана иде, үтәлә иде, тәэмин ителә иде.

[4] инкыйлаб – революция. 1917 елда булган Октябрь революциясе күздә тотыла.

Мин дә үз вазифаны беләидем, ягъни Кырымның имамнары, хатыйблары хозурында, Кырымның Бөек Идарә-и Шәргыя[1] хозурында һәрвакыт һәм һәрҗирдә әдәп сакладым, бу йөздән фәтва бирүче теле белән сүз сөйләү кыюлыкларыннан, мин, әлбәттә, саклана идем.

Беләмен ки, бүгенге көндә сүз сөйләмәк, фикер әйтмәк һәрбер инсанның[2], һәрбер мөэминнең, әлбәттә, мөкаддәс изге хакыдыр. Ләкин бүгенге көндә әһәмиятле мәсьәләләрдә, гомуми мәсьәләләрдә гамәл кагыйдәсе булып китәчәк фәтваләр бәян итү, язу яки игълан итү бары тик идарәи шәргыяләрнең, бары тик дини нәзарәтләрнең хакы булуы, әлбәттә, зарурдыр.

Бу фикерләремне мин моннан биш-ун ел элек инде ишеттергән идем, язган идем. Соңрак аларны «*Ислам милләтләренә*» кебек, «*Шәригать әсасләре*»[3] кебек китапларымда кабаттан нәшер иткән идем.

Әгәр болай булса иде, һәм дә фикердә иреклелек хакы, һәм дә һәр хосуста иҗтиһат куәте мөселманнарның һәрберсе өчен тәэмин ителеп торса иде, ул чакта гамәл кагыйдәсе,

[1] Бөек Идарә-и Шәргыя – Кырым автономияле совет социалистик Республикасында 1923 елның 5нче февралендә барлыкка килгән бу оешманың рәсми исеме «Народное управление религиозными делами мусульман Крыма» була. Әлеге дини оешма Кырымда 1831нче елдан бирле эшләп килгән Таврия мөселманнары Диния нәзарәте урынына оештырылган була. Совет хөкүмәте тарафыннан 1944 елда Кырым татарларын көчләп читкә сөрү нәтиҗәсендә Кырымда ислам, мөселманлык һәм мөселманнарның дини оешмалары тарихы өзелә.

[2] инсан – кеше.

[3] «Шәригать әсасләре» – Муса әфәнденең 1917 елда Петроградта чыккан китабы. Китапта исламның кешеләр тарафыннан иҗат ителгән мәдәни һәм күктән иңгән сәмави шәригать-законнарга мөнәсәбәте турында сүз йөртелә. Моннан тыш ислам шәригатенең хакыйкыйлыгы, аның нигезләре һәм чыганаклары; Коръән кәримнең кешеләргә карата куйган таләпләренең аңлатмасы; Коръән кәримнең чынбарлык күренешләренә, табигать дөньясының хакыйкатьләренә караган ачык, аңлаешлы һәм күпсанлы бәяннары; шәригатьнең ике төркем хөкемнәре; хиҗаб мәсьәләсен хәл итү һәм башка бик күп мәсьәләләр каралган.

хәят кануны булырга тиешле булган ислам тәгълиматы һәр заманның хаҗәтләренә күрә, һәр урынның хәлләре-үзенчәлекләренә күрә, һәрбер мәдәниятнең дәрәҗәләренә күрә, ачык шәкелдә тәмам[1] төпле-нигезле бер рәвештә тәгайен кыйлыныр иде[2], җәелер иде, танылыр иде.

Болай булса иде, иҗтиһатның мәңге дәвам итүе, мөҗтәһитләрнең[3] һәр җирдә, һәр заманда күплеге, мәзһәбләрнең[4]

[1] тәмам – тулысынча, соң дәрәҗәдә, бөтенләе белән.

[2] тәгайен кыйлыныр иде – билгеле булып, танышып кабул ителер иде.

[3] мөҗтәһит (гарәп.: иҗтиһат кыйлучы, тырышлык иясе) – ислам хокукында махсус бер гыйльми дәрәҗәне белдерә торган төшенчә, гыйльми термин. Мөҗтәһит исеменә лаек булган галим фикъһыда фәтвалар, ягъни шәргый законнар, карарлар, хөкемнәр чыгара ала. Андыйлардан Мөхәммәт пәйгамбәрнең (ﷺ) бөтен сәхабәләре һәм ул сәхабәләрдән белем алган шәкертәре санала. Моннан тыш, фикъһы гыйлеменә, аның теориясе һәм практикасына нигез салган атаклы галимнәр дә мөҗтәһитләрдер. Андыйлардан, мәсәлән, фикъһы юнәлешләрен (мәзһәбләр) булдырып калдырган имам Әбү Хәнифә, имам Мәлик кебекләрне атап була. Болары мөҗтәһит фи-ш-шәргъ, яки мөҗтәһит мотлак, ягъни тулы хокуклы, камил белемле абсолют (мотлак) мөҗтәһитләр. Андыйлар гомум шәригать дәрәҗәсендә фәтвалар чыгара алганнар. Мөселман галимнәренең уртак фикеренчә, ислам тарихының беренче гасырларында иҗат иткән мотлак мөҗтәһитләр дәрәҗәсенә җитәрлек галимнәр алга таба җитешә алмаган. Шуңа күрә мотлак мөҗтәһитләр дәвереннән соң яшәгән һәм фикъһы гыйлемендә эз калдырган башка атаклы галимнәр мөҗтәһит мотлак була алмыйлар. Алар бары тик мөҗтәһит фи-л-мәзһәб яки мөҗтәһит фи-т-тәрҗиһ дәрәҗәләренә ия була алалар. Боларның беренчеләре аерым мәзһәпләр даирәсендә фәтва кыйла алалар, ә тәрҗиһ кыйла алучы мөҗтәһитләр аерым һәм кечкенә фикъһый мәсьәләләрне хәл итү хокукына ия.

[4] мәзһәб – ислам фикъһысына (дини хокук гыйлеменә) кагылышлы рәвештә мәзһәб сүзе теге яки бу методологик нигезләргә корылган юнәлешләрне, хокукый фикер һәм хокукый практика агымнарын белдерә, мәсәлән хәнәфи мәзһәбе (имам Әбу Хәнифә исеменнән), мәлики мәһзәбе (имам Мәлик исеменнән), шәфигый мәзһәбе (имам Шәфигый исеменнән), хәнбәли мәзһәбе (имам Хәнбәл исеменнән).

дә төрлелеге бөек бер иҗтимагый нигъмәт булыр иде, гайәт бәрәкәтле бер илаһи рәхмәт булыр иде. Ислам милләтләрендә бүгенге кебек аптырап катып калганлык калмас иде.

Болай булса иде, иҗтиһатның юкка чыгарылуы нәтиҗәсендә барлыкка килгән бәлаләр ислам милләтләренең калебләрен үтермәгән булырлар иде, мөселманнарның баш миләренә, фикерләренә көчле торгынлык бирмәгән булырлар иде.

Болай булса иде, милли хәятнең мәдәни кануннарын ят чыганаклардан, чит милләтләрдән күчереп кабул итү ихтыяҗларына көчле-гыйззәтле төрекләрнең тырышлыклары мәҗбүр булмас иде.

Аракы-шәраб мәсьәләләрендә Кырым мөселманларының истифталары[1] хозурында мин шуңа күрә дәшми идем. Мәсьәлә, минем карашымча, тәмам ачык булса да, моннан унсигез-унтугыз ел мөкаддәм[2] язылган «*әл-Лөзүмият*»емнең 55–59 сәхифәләрендә бу мәсьәлә бөтен нечкәлекләре белән тәфсилләп аңлатылган булса да, авызым ачып сүз-фәлән ишеттерми идем. Ул чакларда: «Бөек Идарә-и Шәргыягезнең карарына мөрәҗәгать кыйлыгыз!», дигән сүзем белән канәгатьләнә идем.

«Гомуми мәсьәләләрне хәл итмәк һәм хәл иттермәк юлында мөхтәрәм имам әфәнделәр, мөхтәрәм хатыйп әфәнделәр кызыксыну күрсәтсәләр, аларның гамәл кагыйдәсе була алачак нигезле әһәмиятле карарлары Бөек идарә-и шәргыя мәгърифәте белән игълан ителсә, мин дә сезгә кушыла алам. Фикерләремне, уйлануларымны «*Гаср-е мөселманлык*»[3] сәхифәләрендә Русия мөселманнарына, имамнарына, хатыйпларына зур теләк белән, иншаллаһ, мин дә тәкъдим итә алам»,– дия идем.

---

[1] истифта (гарәп.; фәтва эстәү) – нинди дә булса шәргый мәсьәләгә караган фәтваның кирәклегенә үтенеч белдерү.

[2] мөкаддәм – алдан, элек, әүвәл.

[3] «Гаср-е мөселманлы» – Кырым мөселманнарының дини журналы.

Мөселман җәмәгатьчелегенең, мөхтәрәм имам әфәнделәрнең миңа җиткергән истифталары нибары ике бик тә гади, гайәт ачык шәргый мәсьәлә хакында иде:

Беренче мәсьәлә: Хәрам кыйлынган йөзем шәрабе сыман, бүгенге аракы да, ягъни водка да хәрамме? Аракы да нәҗесме[1]?

Икенче мәсьәлә: Йөземнән ширә[2] сыгу, ширәләрне шәрабкә әйләндереп сату Русия мөселманнарына рөхсәт ителә аламы?

Халык бу мәсьәләләргә һәрҗирдә игътибар бирә иде, көчле кызыксынуын белдерә иде. Бу хәлгә мин хәтта бераз гаҗәпләнә дә идем. Ниһаять, кызыксынуларының, игътибарларының сәбәбен бераз аңлый башладым.

Югарыда искә алынган әүвәлге мәсьәлә фикъһы китапларында борынгыдан килгән риваятьләренең тәэсире белән, мөкаллид[3] фәкыйһларның, мәгърур хуҗаларның[4] арадашлыгы белән халык арасында һәркайда таралган гайәт куәтле бер уйдармадан үсеп чыга. Ул уйдырма ошбудыр:

Хәрамлек, нәҗеслек бары тик йөзем шәрабләренә, бары тик хөрмә шәрабләренә хас, имеш! Шәрабләрнең башкалары пакь, имеш, тулысынча хәлал, имеш! Хәтта мәшһүр мөдәррис хуҗаларның берсе: «Урыс водкасы белән абдәст[5] алу өчен рөхсәт ителә ала!»,– дия, имеш.

---

[1] нәҗес – шакшылыгы тизәк дәрәҗәсендә булган начар нәрсә.

[2] ширә – җиләк-җимеш суы; сок.

[3] мөкаллид – (гарәп.: калләдә, ягъни, «охшашланырга», «кабатларга», «ияреpгә» дигән мәгънәләргә ия булган фигыльдән ясалган төп юнәлештәге сыйфат фигыль) – кемгә яки нәрсәгә булса охшашланучы; кабатлаучы; иярүче кеше. Мөкаллид, дип тәкълид кылучы фәкыйһларны атаганнар. Фикъһыга караган төшенчә буларак тәкълид сүзе соңрак дәверләрдә эш иткән фәкыйһларының шәригать хөкемнәрен чыгаруда борынгы атаклы фәкыйһлар, мотлак мөҗтәһитләр чыгарган карарларга һәм хөкемнәргә иярүләрен, шуларны кабатлауларын белдерә.

[4] хуҗа – биредә шәкертләр тәрбияләүче остазлар, мөдәррисләр күздә тотыла.

[5] абдәст – тәһарәт.

Беләмен ки, мондый олы уйдырма – мөкаллид фәкыйһләр арасында киң таралган нәрсә. Ул уйдырма хәтта фикъһы китапларының сәхифәләрендә дә мәбзүлдер[1], язылгандыр. Шул китаплардан ул халык арасында таралды да инде, халыкның эчкечелек бәласен йоктыруына да, азмы-күпме, сәбәпче булды.

Русия татарларында аракы эчү бәласе бар. Хәзерге вакытта туйларда, никах мәҗлесләрендә йөзем шәрабләре һәрвакыт булып тормаса да, урыс водкасы очсыздыр, гадидер, һәрҗирдә, гадәттә, бардыр.

Димәк, урыс водкасы һәрҗирдә бар. Кырымда да никах мәҗлесләренең берсендә аны күрдем: табында кырык градуслык өч шешә бар иде. Сораштым. Кунаклардан берәү: «Шәраб хәрам булса да, аракы хәлалдер»,– диде. Белемсез, өмми[2] бер адәм иде.

Ниһаять, мин мәсьәләнең асылын аңладым. Бу хәл илебездә булган революциянең нәтиҗәсе дә түгел иде, иҗтимагый тетрәнүләрнең дә әсәре түгел иде. Бу эчкечелек бәласе мөкаллид фәкыйһләрнең борынгы заманнардан бирле халыкка биргән тәрбияләренең нәтиҗәсе иде. Мондый манзараларны[3] мин берничә җирдә күрдем. Аптырап күзәтә идем. Тәэсирләнә идем. Табигатьләре саф һәм садә булган халыкның фикерләренә, вөҗданнарына мондый бер уйдырманың мәзһәб юлы белән, дин исеме белән ныклы сурәттә йогуы вөҗданымны да, калебемне дә газаплый иде. Кәефем бик бозыла иде.

Әүвәлге мәсьәлә[4] үзенең нигезе ягыннан гайәт зәгыйфь, тәмам бозык бер нәрсә булса да, аңа бирелергә тиешле җавап гайәт җиңел вә гайәт ачык булса да, халыкның гакыйдәләренә[5] үтеп кергән бу көчле уйдырманың куәте белән, мәсьәлә

[1] мәбзүл – телгә алынган, китерелгән.

[2] өмми – уку йортларында укымаган кеше; укый-яза белми торган кеше.

[3] манзара – күренеш.

[4] Ягъни: «Хәрам кыйлынган йөзем шәрабе сыман, бүгенге аракы да хәрамме? Аракы да нәҗесме?» – дигән сораулар күздә тотыла.

[5] гакыйдә (гарәп.; шулай ук – игътикад) – дини төшенчә буларак мөселман кеше шикләнмәстән инанырга тиешле булган нәрсәләр,

гайәт мөшкел[1] булып калды. Хәнәфи мәзһәбенә тәкълид кыйлу[2] зарури булган хәлдә әлеге мәсьәләгә карата тиешле булган җавапны бирү һич тә мөмкин булмаган бер нәрсә булып кала, чөнки хәнәфи мәзһәбенең хөкеменә күрә: «Аракы дөрес нәрсә, ул, әлбәттә, хәлалдер, ул, әлбәттә, пакьтер»,– дип әйтү тиешле булып кала[3].

Ләкин бу мәсьәлә икътисади табигатьле зур бер зарурәтдән үсеп чыга. Ул тормышның әһәмиятле, зарурәтле бер мәсьәләседер, чөнки Кырымда күпчелекне тәшкил иткән бер өлеш халыкның бөтен тәэминаты[4] бакчачылыктыр, йөзем үстерүдер. Әгәр дә аларга ширә сыгу, ширә саклау, шәраб сату рөхсәт ителмәсә, күпсанлы халыкның үзләре дә, бөтен гаиләләре дә бөтен тәэминатләреннән аерылып, ниһаять, җирләреннән, бакларыннан тәмам мәхрүм булып, тәмам акчасыз калып, нәтиҗәдә үзләре дә, гаиләләре дә башкаларның кулларында әсир булып калачак.

---

мәсәлән, Аллаһның барлыгына инану, Мөхәммәт пәйгамбәрнең Аллаһ илчесе һәм пәйгамбәре булуына инану һ.б. Болары иман шарты дип тә атала. Әмма биредә Муса әфәнде әлеге терминны халык арасында гадәти булган, күнегелгән, таралыш тапкан ышануларның берсен белдерер өчен кулланган.

[1] мөшкел – кыен, катаулы.

[2] тәкълид кыйлу – биредә борынгы заман хәнәфи мәзһәбенә караган фәкыйһләр тарафыннан кабул ителгән шәргый хөкемнәргә иярү, аларны үтәү.

[3] Биредә автор борынгы заман атаклы дин галимнәреннән калган карашларның һәм хөкемнәрнең изге мирас буларак кабул итүнең һәм ул карашларга иярү тиешлеген катгый кагыйдә буларак таләп иткән һәм гамәлгә ашырырга мәҗбүр иткән тәкълид традициясенең никадәр зарарлы булуын ассызыклый. Чыннан да, аракы мәсьәләсен башкача хәл итү, ягъни аракының йөзем шәрабе кебек үк бер хәрам булуын таныган очракта, изгеләштерелгән тәкълиднең кагыйдәсе дә үтәлми, борынгы абруйлы шәригатьче галимнәрнең белемнәренә дә тап төшерелә һәм алардан калган «изге» мирасның изгелегенә дә шик белдерелә.

[4] тәэминат – яшәешне тәэмин итеп тору чаралары; матди керем һәм табыш биреп торучы кәсеп, һөнәр һәм башка төр эшчәнлекләр.

Бу мәсьәлә хәят мәсьәләседер. Бу мәсьәлә әһәмияте гайәт зур булган икътисад мәсьәләседер. Хәнәфиләрнең «*Бәдаигъ*»[1] кебек иң ышанычлы, иң асыл фикъһы китапларында нигезле бер фәтва буларак җаваплары да мөмкин кадәр ачыклык белән язылган гайәт мәшһүр бер мәсьәләдер.

«Йөземнән ширә сыгып шәраб җитештергәннән соң, шәрабләрен Инглитәрә[2] кеби, Чин[3] кебек җирләрдә сатулары милләтләрнең һәрберенә, бүгенге Русия кебек җирдә Госвиноларга, яки шәраб подвалларына сату, би-л-иттифак[4], рөхсәт ителәдер. Ислам дәүләтләрендә зиммиләргә[5], мөгаһидләргә[6], мөстәэминнәргә[7] сатмак күпчелекнең карашына күрә, әлбәттә, рөхсәттер».

Хәнәфиләргә фәхер[8] була алырлык, һәм дә хәнәфиләрнең башка мәзһәбләрдән өстен чыгулары өчен өстәмә куәт бирә алырлык «*Бәдаигъ*» кебек ышанычлы мөгътәбәр китапның эчемлекләргә багышланган бүлекләрендә, аерым алганда, җиденче томның 40 нчы сәхифәсендә бу мәсьәлә бөтен нечкәлекләре белән, бөтен куәте белән бәян кыйлынмышдыр.

---

[1] «Бәдаигъ» (тулы исеме: «Бәдаигъ әс-санаигъ фи тәртиб әш-шәригать») – хәнәфи мәзһәбе фикъһысында киң таралыш тапкан күп томлы шәргый рисалә. Аны Мәвараәннәһерле галим Галәветдин Әбу Бәкер бин Мәсгут Әхмәт әл-Кашани (м. 1191 ваф.) язган булган.

[2] Инглитәрә – Англия.

[3] Чин (шулай ук: Чин-Мачин) – Кытайның Шәрык халыклары аласында кабул ителгән исеме.

[4] би-л-иттифак – уртак фикергә күрә.

[5] зиммиләр – шәригать кануннары буенча яшәгән ислам дәүләтләрендә яши торган мөселман булмаган халыклар.

[6] мөгаһидләр – шәригать кануннары буенча яшәгән ислам дәүләтләрендә мөселманнар белән килешүләр (гаһыд) корып яши торган мөселман булмаган халыклар.

[7] мөстәэминнәр – башка диннәр тотып та, мөселманнардан яклау-химая үтенеп, мөселманнарның канаты астында яшәгән халыклар.

[8] фәхер – дан, мәртәбә.

Халыкның дөньяда яшәешләренә, диннәренә, әдәп-әхлакларына, гаиләләренә зыян салачак үзләренең бу уйдырмаларын мөмкин кадәр канәгатьлелек хисе белән, зур кыюлык белән тараткан мөкаллид фәкыйһләр, гафил-надан мөдәррисхуҗалар халыкның хәятләренә, ихтыяҗларына кагылышлы булган гайәт әһәмиятле мәсьәләләр хакында ни йөзләре белән бу кадәр олы гамьсезлек күрсәттеләр? Ни өчен гамьсезлек кыйлдылар?

Моның сәбәпләрен тану теле белән, нәсыйхәт юлы белән ачыктан ачык бәян итә алсак иде, бөек гыйбрәтле хәлләр, бәлки, мәгълүм булыр иделәр.

Мин бу мәсьәләләрне бәян иттем. Җавапларын да көтеб хәнәфиядән[1] китердем. Шуларга тәкълид юлы белән бирелгән җавап җитәрлек булса: «Мәсьәләләр хәл кыйлынды, җаваплары да ачык мәгълүм булды»,– дип әйтү мөмкин булыр:

«Аракы, нәкъ шәраб кебек, нәкъ хәмер кебек, әлбәттә, хәрамдер. Йөземнең ширәләрен сыгу һәр җирдә һәрвакыт рөхсәт ителә. Кырым кебек, Төркестан кебек җирләрдә шәрабләрне винный подвалларга, Госвиноларга сатмак, әлбәттә, җаъиздер[2]».

Хәнәфи мәзһәбендәге имам хәзрәтләренең биргән җаваплары шушыдыр.

Бөек сәләфнең[3] булдыклы оста каләме белән язылган хәдис китаплары, бөтен мәзһәбләрнең көтеб фикъһияләре[4] мәйдандадыр. Хәнәфиләрнең «*Һидая*»[5] кебек, «*Бәдаигъ*» кебек

---

[1] көтеб хәнәфия – хәнәфи мәзһәбенә караган фикъһы китаплары.

[2] җаъиз – рөхсәт ителгән, тыелмаган эш.

[3] сәләф – борынгы заманда яшәгән игелекле мөселман бабалар, ягъни пәйгамбәребезнең (ﷺ) сәхабәләре, алардан гыйлем алган шәкертләр (тәбигыйннар) һәм шул шәкертләрнең шәкертләре (тәбгытәбигыйннар).

[4] көтеб фикъһия – фикъһы гыйлемен бәян итүче китаплар.

[5] «Һидая» (тулы исеме: «Һидаятүн фи фөругы әл-фикъһы») – XII йөздә Мәвараәннәһерле дин галиме мәшһүр фәкыйһ Борһанетдин Маргинани тарафыннан шәригатькә, ислам канунына киң күзәтү буларак язылган фундаменталь хезмәт. Аңа атап язылган шәрехләр аша «Һидая»» Үзәк Азиядә, Төньяк Кавказда, Русиядә яшәгән та-

көтеб фикъһияләре дә бәлки һәммәгездә, шәт, бардыр. Бүгенге иҗтимагый хаҗәтләрегезнең ачык һәм гүзәл җаваплары да көтеб фикъһиягездә бардыр. Аларны бары тик укымак зәхмәте[1] белән генә дә югарыда телгә алынган мәсьәләләр хәл кыйлына ала.

Рәхим итегез, укыгыз. Болай итү гайәт аз бер зәхмәттер, ләкин гүзәл бер эштер.

---

тарларда, Госманлы Дәүләт-и Галиясендә, Һиндыстанда һәм хәнәфи мәзһәбенә ияргән гарәпләрдә киң кулланылыш тапкан булган. Хәзерге заманда «Һидая» мөселман уку йортларында шәригать буенча, хәнәфи фикъһы буенча төп уку китабы булып тора.

[1] зәхмәт – хезмәт күрсәтү, тырышлык күрсәтү.

# Муса әфәнденең Зиннәт Бүрегә язган хаты[1]

Сезгә әлбәттә мәгълүмдер, соңы елларда ике мәртәбә ислам җирләренә сәяхәт иттем. Бөтен Русия мөселманнарының вәкиле булып, ислам мөэтәмәренә[2] сәфәр иде. Мондый хосусларда паспорт алу җиңел эш. Шуңа күрә ике тапкыр паспорт ала алдым. Гади сәяхәт түгел, гадәттән тыш бер сәфәр иде. Ләкин Финляндия җиренә сәяхәтем (…)[3] сәяхәттер. Мондый сәяхәтләргә паспорт алу мәшәкате мондый заманнарда бераз күбрәк була. Алай да, иншаллаһ, алырмын; Финляндия мөселманнарын зиярәт итәрмен, иншаллаһ. Фин-Төрек гарантларының низамнамәсен[4] укыдым. Яхшы, ярыйсы. Ләкин мәктәп-тәрбия мәсьәләсе гаять-гаять мәшәкатьле бер эштер. Бу мәсьәлә хакында арагызда каршылыклар чыккан булса, каршы җәмәгатьне сез бераз мәгъзүр[5] күрегез. Сезнең алты еллык милли төрек мәктәбендә укып тәмам иткән балалар әзерләнүсез фин мәктәпләренең югарыларына кабул кыйлынырлык булсалар ярый. Әгәр дә сезнең мәктәптә укып чыккан балалар фин мәктәпләреннән мәхрум калырлык булса, бу очракта бераз уйлану тиеш. Русиядә «Мөхәммәдия»ләр, «Госмания»ләр, «Галия»ләр Русия мөселманнарының милли хаҗәтләрен үтәүдән тәмам гаҗиз иделәр: шәкертләре ни

[1] Чыганак: Battal-Taymas, A. Musa Carullah Bigi. Kişiliği, fikir hayatı ve eserleri. Kazanlı Türk Meşhurlarından II. İstanbul, 1958. S. 56–61. (Документ татар теленә тәрҗемә ителде).

[2] мөэтәмәр – корылтай.

[3] Укылышы мөмкин булмаган сүзләр.

[4] 1918 елның 21 февралендә Төркия Финляндиянең мөстәкыйльлеген таный, 1920 елның 20 маенда ике ил арасында рәсми дипломатик мөнәсәбәтләр корыла. Муса әфәнде Төркия белән Финляндия арасында 1926 елның 4 гыйнварында имзаланган Дуслык турындагы килешүне, яки аның нигезендә кабул ителгән башка документларны күздә тота.

[5] мәгъзүр – гозерле; акланырлык сәбәп иясе булу.

ары, ни бире кала иде; ни русча, ни татарча, ни төрекчә белә иде. Бу мәгълүмдер. Минем көчем Барудиләрдән, Бубиләрдән ким түгел иде; ләкин мәктәп ачу, мәдрәсә ачу юлында мин йөрмәдем. Милләтнең һәм заманның милли-мәдәни хаҗәтләрен берләштерерлек мәктәп ачу гаять мөшкел эш иде. Шәкертләргә бөтен кирәкләрен бирә алудан гаҗиз мәдрәсәләр милләт балаларын мәдәни мәктәпләрдән, дарел-фөнүннәрдән тәмам мәхрүм итәләр. Шуңа күрә мин үзем мәдрәсә ачмадым. Булганнарына ярдәм итеп, милләт балаларын Русиядәге мәдәни, әдәби, дини хаҗәтләребезне берләштерерлек бер мәктәп хакында баш ватып һаман фикер итә идем. Мәсьәләмне хәл итә алмадым, гаҗиз калдым. Дөньялар тәмам үзгәрде. Иске мәдрәсәләрнең бөтен әсәрләре, эзләре тәмам юкка чыгарылды, тәмам бетте; кадим-җәдит талашу ахмаклыклары калмады. Фронтлар тәмам үзгәрде. Татарларның кадимнәре дә, җәдитләре дә һәммәсе «инде берләшик» дисәләр дә, бүген гаять куәтле «отбор», нык иләү, сөзү башланды. Инде бүген мин мәдрәсә ачу юлында сәгъйи иттем[1]. Ярарлык мәдрәсә ачу хәл ителерлек шикелле мөшкел бер эш булса да, мин хәрәкәт итәм. Моның белән бергә милләт балаларын, татар балаларының һәрберен хөкүмәт мәктәпләренең һәрберенә сөрәм, дәлилләр китерәм. Булачак мәдрәсәм, ачылачак мәктәбем татар балаларын хөкүмәт мәктәпләреннән мәхрүм итү юлында булмас, иншаллаһ. Мин әүвәлге кебек татар балаларын хөкүмәт мәктәпләренә дәллиләп торсам да, Төркестан, казакъ, татар балалары арасыннан ислам голүмнәренә, Коръән кәрим голүмнәренә, гарәп әдәбиятына рагъбәте[2] бар шәкертләр өчен әдәби мәдрәсә ачу юлында сәгъйи итәм. Мәдәни, дөнья мәктәпләренә барачак балалар хакында мәдрәсәм тыгызламас; һичберсен юллардан аермас. Мәдрәсәм ислам галимнәренә, ислам мөҗтәһидләренә махсус булыр. Ислам галиме булачак рагъбәтле шәкертләргә мәдәният мәдрәсәләренә юл ачу юлында сәгъйи итәчәк. Минем мәдрәсәм була калса, зарурәт юлында вакытлы бер мәдрәсә булыр. Һәм минем укучы

[1] сәгъйи иттем – көч куйдым, тырыштым.

[2] рагъбәт – көчле теләк.

шәкертләрнең чамадан тыш иҗтиһадлары, мәшәкатьләнүләре белән генә мөмкин була алыр.

Финляндия шикелле, Русия шикелле дәүләтләрдә гомер итүче ислам балаларына бүген бары тик бер генә юл калыр: хөкүмәт мәктәпләренә тулмак, мәдәни мәктәпләрнең һәрберен тутырмак; диннәрен, әдәпләрен, гыйлем-е хәлләрен[1] вакытына кадәр өйдә, мәчеттә ата-анарыннан, хәзрәтләрдән, хосусый мөгаллимнәрдән укып тормак. Мөгаллимнәрдән-хәзрәтләрдән дин дәресләре, милли дәресләрне укытканда, балаларның буш айларына игътибар итү тиеш. Соңыннан бер сәгатьтән артык итмәү тиеш. Оста мөгаллим булса, мөҗтәһид хәзрәт булса, юллы-суллы укытканда байтак нәрсә өйрәтү мөмкин булыр.

Сезгә мәгълүм, Финляндиягә һәр авылда, һәр шәһәрдә төрек мәктәбе ачу мөмкин түгел; бер шәһәрдә ачылачак мәктәпкә Финляндиядәге бөтен ислам балаларын туплау мөмкин түгел. Шулай булгач, вакытына кадәр ялгыз бер генә чара, ялгыз бер генә юл кала: төрек балаларын хөкүмәт мәктәпләрендә укыту, дин дәресләрен, милләт сабакларын буш айларда хосусый сурәттә яхшы мөгаллимнән укыту. Ярар иде, Таммерфорста яки Һелсинкидә ачылычак төрек мәктәбенә бөтен Финляндия мөселманнарының бөтен балалары төпләнә алсалар иде; ярар иде, төрек мәктәбе ислам балалары хакында фин мәктәпләре урынына торырлык булса иде; ярар иде, төрек мәктәбенең бөтен мөгаллимнәре, мөдирләре мөселман булып, төрек мәктәбе ислам балаларын башка зур мәктәпләрдән мәхрүм итмәсә иде. Мондый бер мәктәп Төркиядән дәгъвәт ителәчәк динле, әдәпле, мәгълүматлы дүрт-биш булдыклы мөгаллимнәр янына финнардан да кушылачак берничә мөгаллим, мөдир булса, ихтимал, мөмкин булыр. Ләкин дәвамы гаять авыр булыр, расходы тәкатьтән тәмам тыш булыр. Шуңа күрә, минем фикеремчә, Финляндиядәге төрек балаларын фин, швед яки нимес мәктәпләренә йөртү; ислам тәрбиясе хосусларында хосусый сурәттә сәгъйи итү итеш. Ислам бала-

[1] гыйлеме хәл – башлангыч дини белемне үз эченә алган голүмнәр.

ларына дин дәресләрен, милли дәресләрне Галимҗан әфәнде Идриси кебек мәгълүматлы бәйләр яки Вәли-Әхмәт хәзрәт Хәким кебек мөҗәһид[1] имамнар яхшы, монтазам, җиңел сурәттә әгәр дә укытсалар, һәрберенә рәхмәт әйтегез, вакытына кадәр канәгать кыйлыңыз. Моның өстенә, әгәр дә мәктәп ачу мөмкинлеге сезгә мәгълүм булса, ачылганнан соң да дәвамы ихтимал тотса, ярдәмчегез Аллаһ, боерыгыз[2]; мәшәкатьле булса да сәгъйи итегез, бәлки барып чыгар. Низаг зарур түгел, талашу, дошманлашу хаҗәт түгел, ара бозылу лязем түгел; афарузлар-мафарузлар[3] акыл эше түгел.

Хәтерегездә юктыр, мин тәмам 25 ел элек бер китап язып, ислам мәктәпләренең, мәдрәсәләренең дәһшәтле аянычлы хәлләрен тәфсыйль иткән[4] идем. Соңыннан, ягъни 23 ел элек «Әл-Лөзүмият» исемле бер китап язып, ислам шәкертләренә хөррият дәресләре биргән идем.

Хөррият ике әдәпкә өйрәтә:

1) үз күзең белән күр, үз акылың белән фикер ит; үз хөрриятең белән бергә башкаларның хөрриятләрен дә җәмыг ит[5]! Үз фикереңне әйт, сиңа каршы бер кеше каршы чыкса, мөхалифеңне[6] дә зур хөрмәт белән тыңла, мөхакәмә[7] ит, мөназара[8] ит, ләкин дуслаша бел, үз итә бел!

2) Һәр хосуста, һәр мәсьәләдә башкаларга тәмам башка бер адәм бул, ләкин милли, дини эшләрдә бер җан, бер тән булмасагыз, җәмәгать эчендә чын күңелдән җәмәгать адәме бул. 23 ел элек язылган китабымда хөррият шулай бәян кыйлынган иде. Хәтерегездәдер, җиде ел элек минем бер китабымны сез бастырган идегез[9]. Китабым бәлки сезнең кулыгыздадыр. 59

[1] мөҗәһид – тырыш.

[2] боерыгыз – дәвам итегез.

[3] афаруз-мафаруз – бүлгәләнү.

[4] тәфсыйль иткән идем – тәфсилләп аңлаткан идем.

[5] җәмыг ит – куш.

[6] мөхалиф – каршы чыгучы, оппонент.

[7] мөхакәмә – хөкем чыгару; мәсьәләне уртага салып хәл итү.

[8] мөназара – сүз көрәштерү, бәхәсләшү.

[9] Сүз «Ислам милләтләренә» («Исламият әлифбасы») исемле китап турында бара.

нчы сәхифәдә 96 нчы маддә укысагыз, күрерсез. Исламияттә бары тик йөрәкләр берлеге могътәбәрдер[1]. Фикерләр никадәр төрле булса да булсын, фикерләр төрлелегендә зарар юк. Калеб берлеге исламның иң бөек рөкынедер. Китабым сезнең нәшерегездер. Кулыгызга алыгыз да, бер күрегез. Бу маддә татар канында булган зур авыру өчен гүзәл бер рецепт иде. Басу вакытында корректорлык кыйлган хөрмәтле Гаяз әфәнде әгәр ул маддәдәге дәресемне хәтередә тоткан булса иде, Галимҗан әфәнде Идриси кебек хөрмәтле яшьләр хакында «Милли Юл»да[2] юк-бар нәрсәләрен ихтимал язмаган булыр иде. Гаҗәп, безнең әдипләребездә вак хәлләр, вак фикерләр хөкем сөрә…

Финляндия мөселманнарының һәрберенә догаларымны укырсыз. Инкыйлаб соңында дөньялар һәр җирдә тигезләнде. Русия, Төркия, Финляндия араларында үзгәлек калмады. Туган җирегездән туйган җирегез яхшы хикмәте белән бүген гамәл кыйлып, рәхәт торыгыз, сәгъйи итегез: бөтен җир йөзен җәннәт ясый алмасагыз да, һәр җирдә үз йортыгызны, үз бүлмәләрегезне иман нуры белән, рухыгыз куәте белән җәннәт ясагыз. Һәр мөэмин өчен Коръән кәрим ике җәннәт вәгъдә итте: берсе – Аллаһ хозурында мәңгелек җәннәт; бере – җир йөзендә, кешенең үз йортында, үз бүлмәсендә…

Бу заманда, әйтик, һәрнәрсә рөхсәт ителде. Ялңыз мәдәният дөньясында торучы мөселманнарның үзара бер-бере белән дошманлыклары хәрамдыр; талашулары рөхсәт түгел.

Кабул итсәгез дә, итмәсәгез дә, нәсихәт юлы белән сезгә дә, бөтен Финляндия мөселманнарына да Коръән кәрим

[1] Могтәбәр – хөрмәтле, кадерле.

[2] «Милли юл» («Яңа милли юл») – 1928–1939 елларда Гаяз Исхакый тарафыннан эмиграциядә (Берлинда) чыгарылган татар журналы. Җәмгысы 136 сан чыга. Гомумән, 1905–1945 елларда һәм Икенче җиһан сугышыннан соң, Төркиядә, Маҗарстанда, Алманиядә, Ляхстанда (Польша), Чинда (Кытай), Япониядә, Финляндиядә, Швециядә, Румыниядә һәм АКШта типографик ысул белән 50-дән артык татар телле газета һәм журналлар чыгарылган. (Галямутдинов А. И. Журнал «Милли юл» (1928–1939 гг.) в системе татарской эмигрантской прессы. Автореферат).

әмере, Шаригъ хәким[1] сүзедер. Үз хөрриятегезне дә, башкаларның хөрриятләрен дә саклагыз. Хосусан имам әфәнденең хөрмәтен ригая кыйлыгыз.

… Бөек төрек дөньясы минем артымнан (ияреп) китмәсә дә, бөек раһбәрләрнең артыннан йөрсә дә, сүземне, фикеремне мин гаять ачык итеп әйттем…

Төркия китапларын җибәрә алсагыз, ярар иде. Иншаллаһ, тапшырылыр, югалмас. Үтенәм, Бөек Гази хәзрәтләренең[2] гарәп хәрефе белән басылган «Нотык»ын[3] һәм дә булса әһәмиятле башка китапларны җибәрә алсагыз, ярар иде. «Нотык»ның русча тәрҗемәсе миндә бар, тәрҗемәсе гаять яхшы; хәтта басмасы төрекчә басмасыннан да яхшырак. Кодрәтле, хөрмәтле биш адәм тәрҗемә итүдә катнашкан. Гаять тугры, дөрес тәрҗемә иткәннәр. Сатыла. Бәһасе җиде рубль; ләкин (бәһасенә) торырлык, акча әрәм түгел.

*Зур ихтирам белән, Муса Җаруллаһ.*
*Ленинград, Броницкая 16, кв. 21.*

---

[1] Шаригъ хәким (хикмәт иясе булган шәригатьче) – Мөхәммәт пәйгамбәр.

[2] Бөек Гази хәзрәтләре – Мостафа Кәмал Ататөрек.

[3] «Нотык» – Мостафа Кәмалның 1927 елның 15 октябреннән 20 октябрьгә кадәр алты көн, утыз алты сәгать дәвамында Җөмһүрият халык партиясенең 2нче корылтаена җыелган делегатлар хозурында сөйләгән нотыгы. Нотыкта 1919 елның 19 маенда Төркиянең азатлыгы өчен башланган сугыш белән 1923 елда Төркия Җөмһүриятенә нигез салуга кадәр булган тарихи вакыйгалар бәян ителгән. «Нотык» Төркиянең рәсми тарихының нигезе булып санала.

# Кыйраәт тарихы[1]

«نَزَلَ بِهِ الرُّوحُ الْأَمِينُ» 193 «عَلَى قَلْبِكَ لِتَكُونَ مِنَ الْمُنذِرِينَ» 194 «بِلِسَانٍ
عَرَبِيٍّ مُّبِينٍ» 195 (сүрәт әш-Шөгара)[2].

Иңгән вакытта Коръән тилавәтен ничек булса – шул рәвешле ятлау исламиятнең иң олы фарызларыннан иде. Ул чакта Коръәнне ятлау мәртәбә иде, горурлану сәбәбе иде, кешене ихтирам итүнең бизмәне иде: бер адәмнең хәтер көче никадәр зур булса, ислам җәмгыятендә аның абруй-шәрәфе дә, хөрмәте дә шулкадәр олы була иде. Коръәнне өйрәнү һәм башкаларга өйрәтү ул вакытта иң олы гыйбадәттән санала иде. Хилафәт гасырында кешеләр алдында берәүнең ихтирамы, җәмгыятьтә тоткан урыны аның хәтер көченә күрә иде. Хәтере, ятлау көче никадәр зур булса, җәмгыятьтәге урыны да шулкадәр олы булып, әһле ислам күзендә ихтирамы шулкадәр олуг булыр иде. Гомуми эшләрдә аның фикере, сүзе, карашы шулкадәр кадерле була иде ки, бу йөздән сәхабәләр ятлау мәйданында үтә дә киеренке рәвештә бер-берсе белән ярышалар иде. Коръән укыту, аны өйрәтү мәртәбәсенә ирешә алган кеше хөрмәтнең иң югары дәрәҗәсен казанган берәү кебек исәпләнер иде.

Коръәнне өйрәтү шәрәфенә ирешкән сәхабәләрдән иң мәшһүрләре Габдулла бине Мәсгуд, Зәйд бине Сабит, Гали, Госман, Әбү әд-Дарда, Әбү Муса әл-Әшгари, Әбү бине Кә-

[1] Чыганак: Муса Җаруллаһ Рустуфдуни. Әл-әхруф әл-коръәния вә тарих әл-кыйраәт. Китабу әш-Шатыбийәти ли-имами әл-хуффаз әл-әгълам әл-устаз Аби Мөхәммәд әл-Касим әш-Шатыби радыя Аллаһу ганһу. Казан: Лито-Типография Торговаго Дома «Братья Каримовы», 1907. Б.1–17. (Документ татар теленә тәрҗемә ителде).

[2] Коръәндә 26нчы булып килгән Әш-Шөгара (Шагыйрьләр) сүрәсенең 193–195 нче айәтләре: «аның белән имин Рух иңде» (193); «йөрәгеңә синең, синең кисәтүчеләрдән булуың өчен» (194); «ачыктан-ачык гарәп телендә» (195).

габ, Мәгазь бине Җәбәл, Габдулла бине Габбас, Әбү Зәрр әл-Гыйфари, Талха, Сәгыд бине Габид, Габдулла бине әс-Саиб, Хозәйфә, Гаишә, Хәфса, Өмме Сәләмә, Өмме Вәрака бинте Габдулла.

Сәййидел-вөҗүд хәзрәтләрене исән чакта, һәм дә сәхабәләр гасырында Коръән гарәп теленең бөтен укылыш рәвешләре белән бергә тилавәт ителә, ягъни тавыштан укыла иде. Гарәп телендә кулланыла торган укылыш шәкелләрен һичберсен сәхабәләрнең һичберсе инкяр итми иде. Ләкин сәхабәләрнең кайберләре, [Коръәнне] Сәййидел-вөҗүд хәзрәтләреннән ишетеп үзләштергәнгә күрә, кайбер укылыш шәкелләрен тиешле дип санаганга, кыйраәтләре Коръәннең барлык сүзләрендә гомуми ысулга туры килә иде. Тәхфиф[1], идгам[2], ибдаль[3], ималәә[4], вакыф[5] кебек нәрсәләрдә әйтелеш шәкелләре күп булса да, [андый сәхабәләр] кабул ителгән әйтелеш шәкелләреннән һәр бабта тик берсен [куллануны] тиешле итеп, кыйраәтләре бөтен Коръәндә бер генә шәкелдә башкарыла иде. Ул сәхабә Коръәнне тилавәт итсә, яки кыйраәтне башкаларга өйрәтсә, һәммә Коръәнне даими сурәттә тиешле дип санаган бер ысул белән тилавәт һәм тәгълим итә иде.

Әлеге юл белән Коръәннең башыннан ниһаятенә кадәр гомумиләштерелгән ысулга (*ысул мотарридә*) туры китерелгән күпсанлы кыйраәтләр барлыкка килде. Ләкин Коръәнне яки бер сүрәне башыннан ниһаясенә кадәр тилавәт иткәндә, ул гомумиләштерелгән ысулны тиешле бер ысул итү сәхабәләр гасырында кирәк түгел иде. Шуның белән, кыйраәт тарихының беренче дәвере тәмамланды. Бу дәвер Коръән айәтләрен гарәп телендә кулланыла торган һәртөрле әйтелеш шәкелләре белән һичнинди чикләүләрсез тилавәт кыйлу дәвере иде. Ул

---

[1] тәхфиф – Коръән укылышында авазлар әйтелешен йомшарту.

[2] идгам – Коръән укылышында авазларның үзара охшашландыру.

[3] ибдаль – Коръән укылышында авазларның алмашуы.

[4] ималәә – Коръән укылышында авазларның охшашлануы.

[5] вакыф – Коръән укылышында туктап алу; пауза ясау.

дәвердә Коръәне башыннан ахырына кадәр үз эченә алган бер гомуми ысулны тиешле бер ысул итеп күрсәтү кебек мәшәкать юк иде.

Моннан соң кыйраәт тарихында икенче дәвер башланылды. Бу дәвер табигыйннар[1] дәвере, риваять дәвере иде. Табигыйннарның күпчелеге Коръәнне теге яки бу сәхабәдән ишетеп үзләштергәнгә күрә, кемнән ишетеп ятлаган булса, шул сәхабә ысулы белән Коръәнне тилавәт итәр иде һәм башкаларага өйрәтер иде. Бу дәвердә Коръәнне гарәп телендә кулланыла торган әйтелеш шәкелләренең һәрбере белән тилавәт кыйлуның рөхсәт ителгән булуына инансалар да, риваятьләр күзлегеннән караганда әйтелеш шәкелләренең берсе генә тиешле итеп күрсәтелә иде. Чөнки сәхабәдән сабак алган табигълар[2] сүз әйтелешләрен ничек ишетсәләр, шулай өйрәтәләр иде. Тилавәт хөкемнәрендә чикләү булмаса да, риваять хөкемнәрендә сәхабәдән тапшырылган ысул кысаларыннан чыкмау, әлбәттә, зарури иде. Чөнки табигыйннар сәхабәләрдән ишетеп үзләштергән әйтелеш шәкелләреннән башка әйтелеш шәкелләрен риваять итмәгәннәр.

Шулай итеп, мәгълүм бер ысул белән башкарыла торган кыйраәтләр ислам өммәте арасында таралды һәм тамырланды. Моннан соң һәр төбәктә Коръәнне бер танылган ысулга туры китерелгән бер генә кыйраәт белән тилавәт итә торган булдылар. Бу сәбәптән кыйраәтләр теге яки бу төбәккә беркетелә башлады: Мәккә кыйраәте, Мәдинә кыйраәте, Шам кыйраәте, Күфә кыйраәте, Басра кыйраәте кебек билгеләмәләр барлыкка килде. Коръәнне рөхсәт ителгән әйтелеш шәкелләренең һәркайсысы белән тилавәт итү хокукы бары тик олуг гыйлем ияләре катламына гына хас булып калды. Табигыйннарның һәрбере Коръән тилавәтен әйтелеш рәвешләренең һәрбере белән башкаруны ярый торган нәрсә итеп күрсә дә,

---

[1] табигыйннар – ислам, Коръән гыйлемен теге яки бу сәхабәдән үзләштергән мөселманнар.

[2] табигъ – ислам, Коръән гыйлемен теге яки бу сәхабәдән үзләштергән мөселман.

Коръәнне ятлау эшен җиңеләйтү уе белән, Коръәнне башкаларга һаман бер ысул белән генә өйрәтәләр иде.

Бу ике дәвернең һәрберендә Коръән өйрәтүнең мәртәбәсе иң олы дәрәҗә булып санала иде. Ул дәрәҗә бары тик ышанычлы гыйлем ияләренә, гаделлек михрабында имамлыклары расланган бөек шәхесләргә махсус булган белем буларак кабул ителә иде. Сәхабәләрдән соң Коръән өйрәтүче дәрәҗәсенә ирешә алучылар ошбу шәхесләрдер: Сәгыйд бин әл-Мосыйб, Горвә бин әз-Зөбәер, Салим бин Габдуллаһ, Сөләйман бине Йасар, Гата ибне Йасар, Мөгаз бин әл-Харис, Зәед бин Әсләм – Габид бин Гамир, Гата бин Әбү Рийах, Тавус ибне Кәйсан, Мөҗаһид бин Җәбир, Гакрәмә – Могыйрә бине Әби Шиһаб әл-Мәхзүми, Хәлифә бин Сәгыйд, Габдуллаһ бине Гамир, Габдуллаһ бине Кайс – Галкамә, Әл-Әсвад, Мәсрук, Зәрр бин Хәмиш, Гобәйдә әс-Сәлмани, Гамру бине Шөрахбил, әл-Харис бин Кайс, Гамру бин Мәймүн, Сәгыйд бине Җәбир, Габид бине Фаддалә, Гамир бине Шөрахбил әш-Шәгъби, Ибраһим ән-Нәхъгый, Әбү әл-Галия әр-Рияхи, Әбү Рижа әл-Гутари, Насыр бин Гасыйм, Йәхъйә бине Йәгъмир, әл-Хәсән әл-Басрый, Мөхәммәд бине Сирин, Катада, Кагънәб бин Кагънәб әл-Гадәви, Сәлам бине Сөләйман.

Бу табигыйннәрдән соң: Әбү Җәгъфәр Йәзид, Шәйбә бине ән-Нәссах, Нафигъ бине Әбү Нәгыйм, Габдуллаһ бин Күшәер, Хәмид бине Кайс, Мөхәммәд бине Мохыйсин, Готбә бине Кайс, Исмәгыйль бине Габдуллаһ, Йәхсә бине әл-Харис әз-Зөмари, Шариг әл-Хадзрами, Йәхъйә бине Вассаб, Гасим бине Әби ән-Нәҗвәдә, Әбү Хәнифә, Сөләйман әл-Әгъмаш, Хәмзә, Кәсаи, Шогъбә, Хафс бине Сөләйман, Габдуллаһ бине Исхак, Гайсә бине Гомәр, Әбү Гамру бин әл-Галә, Йагъкуб әл-Хаздрами, Гасим әл-Җәхдәри, Йәхъйә әл-Бәзиди. Боларның һәм болар дәрәҗәсендә булган затларның һәрбере ислам галәмендә исемнәре хөрмәт ителгән иң олы галим булып, Коръән укыту мәртәбәсенә, Коръәнгә өйрәтүче шәрәфенә ирешкән.

Бу дәвер һиҗри ел исәбе белән өченче гасыр башына кадәр сузылып, моннан соң Коръән укылышларын теркәү дәвере башланылды.

Кыйраәтләрне иң беренче булып бер китапта җыйган зат ислам гыйлемнәренең имамы Әбү Габид әл-Касим бин Сәлам хәзрәтләре иде. 152 нче елда Һиратта[1] дөньяга килеп һиҗри 224 нче елда Мәдинә-и мөнәввәрәдә рәхмәт-е Ходайга иреште. Башлангыч белемне Һиратта үзләштереп, ул вакытта ислам гыйлемнәренең мәркәзе булган шәһәрләргә китеп, гыйлем туплаган. Үз заманында ислам гыйлемендә чын мәгънәсендә беренче зат, ягъни имам иде. Иң беренче булып мәгълүм булмаган хәдисләр (*гарибел-хәдис*) турында китап язган галим дә ул иде. Беренче мәртәбә Коръән кыйраәтләрен бер китапда җыйган да ул иде. Егерме биш имамнан тапшырылган кыйраәт рәвешләрен риваять итеп бер китап язган иде. Моннан соң Әхмәд бин Җөбәер әл-Күфи хәзрәтләре Мәккә, Мәдинә, Шамия, Күфия Басрыя кыйраәтләрен бер китапта туплады. Һиҗри 258 нче елда вафат булды. Моннан соң казый Исмәгыйль әл-Мәлики егерме имамның кыйраәтләрен бер китапта җыйды. Үзе һиҗри 282 нче елда вафат булды. Моннан соң Әбү Җәгъфәр Мөхәммәд бине Җәрир әт-Табари хәзрәтләре бер олы тәэлиф итеп[2], анда егермедән артык имамнарның кыйраәтләрен тәфсилләп бәян итте. Мөхәммәд бин Җәрир хәзрәтләре мөстәкыйль бер мәзһәб иясе һәм олы мөҗтәһид галим иде. Тәфсир, хәдис, тарих кебек фәннәрдә имам, ягъни әйдәп барган галим иде. Ул һиҗри 224 сәнәдә Табаристанда[3] дөньяга килеп, һиҗри 310 елда Багъдадта вафат булды. Моннан соң Әбү Бәкер бине Мөхәммәд бине Әхмәд әд-Дажуни хәзрәтләре кыйраәт буенча бер китаб язып, Әбү Җәгъфәр Йәзид бине әл-Кагъкаг хәзрәтләренең кайраәтен иң беренче булып теркәп калган кеше булды. Һиҗри 320 нче елда вафат булды. Моннан соң Әбү Бәкер Мөҗаһид хәзрәтләре Нәфигъ, Ибне Кәсир, Ибне әл-Галә, Ибне Гамир, Гасим, Хәмзә, Кәсаи кебек имамнарның кыйраәтләрен бер китапта җыеп, язган хезмәтендә иң беренче булып җиде кыйраәт белән чикләнгән

---

[1] Һират – хәзерге Әфганстандагы Герат шәһәре.

[2] тәэлиф итеп – китап язу буенча хезмәт башкарып; китап язып.

[3] Табаристан – хәзерге Иран җирләрендә Хәзәр диңгезенең көньяк ярлары буенда урнашкан тарихи төбәкнең исеме.

галим иде. Ибне Мөҗаһиднең китабы гыйлем-е кыйраәттә танылып китеп, әлеге җиде имамның кыйраәтләре ислам галәмендә «Кыйраәт сәбга» исеме белән билгеле булдылар. Мондый шөһрәт сәбәбе белән әһле исламның күбесе җиде кыйраәтне җиде хәреф дип уйлый башладылар. Җиде имам белән чикләнү яман тәэсирдән котылмады. Ибне Мөҗаһид хәзрәтләренә ияреп Әбү Гамру Госман бине Сәгыйд әд-Дани хәзрәтләре җиде кыйраәт турында «әт-Тәйсир» исемле бер китап язды. Янә «Җамигъ әл-бәян» исемле зур бер китап язып, анда җиде кыйраәтнең биш йөздән артык риваятьләрен туплады. Һиҗри 444 нче елда вафат булды. Шул елларда Әбү әл-Касим Йосыф бине Гали бин Җәббара әл-Һәзли хәзрәтләре Мәгърибтән[1] Мәшрикъка[2] сәфәр итеп, бөтен ислам илләрен зиярәт итте. Өч йөз алтмыш биш шәйехтән Коръән гыйлемнәрен үзләштерде. Соңыннан «әл-Кямил» исемле бер китап язып, анда илле имамнан калган кыйраәтләрне җыеп, 1459 риваять урнаштырды. Үзе һиҗри 465 нче елда вафат булды. Бу елларда Мәккәдә Әбү Мәгъшәр әт-Табари сикез кыйраәт турында «әт-Тәлхыйс» исемле бер китаб язып, бер мең биш йөз илле риваять туплады. 488 нче елда вафат булды. Моннан соң Әбү әл-Касим әл-Искәндәрани «әл-Җамигъ әл-әкбар вәл-бәхер әл-әзһар» исемле бер китап язып, җиде мең риваять туплаган. Ул 629 нчы сәнәдә вафат булды.

Бу өченче дәвердә, ягъни кыйраәтләрне теркәү дәверендә әһле исламның гомуме Коръәнне үзләренең төбәкләрендә мәгълүм булган бер кыйраәт белән тилавәт итә торган булсалар да, кыйраәт галимнәре Коръәнне кыйраәт китапларында тупланылган кыйраәтләрнең барысы белән дә укырга өйрәтәләр иде. Моның тәэсире белән кыйраәт гыйлемен үзләштерү озак вакыт таләп итә иде, һәм ул өйрәнү өчен катлаулы булган гыйлемнәр сафына керде. Коръәннең укылыш рәвешләре катлаулы булмасалар да, имамнардан тапшырылган риваятьтә ялгышмас өчен, хаталанмас өчен кый-

[1] Мәгъриб – кояш байый торган як, көнбатыш; Мисырдан көнбатышка таба урнашкан ислам җирләре.

[2] Мәшрикъ – кояш чыга торган як, Шәрык, көнчыгыш.

раәт гыйлемен үзләштерүгә озак вакыт сарыф итәргә туры килә иде. Тик гыйлем таләп иткән һәрбер адәмнең вакыты моңа мөмкинлек бирми иде. Бу хәлнең этәрүе белән галәме исламда «әһле кыйраәт», ягъни «кыйраәт осталары» исемле махсус бер сыйныф барлыкка килде. Бу сыйныф «гыйлем-е кыйраәт»тә тирәнгә кереп киткәнлеге аркасында кулланылышта булган башка гыйлемнәрдә белемнәрен киңәйтә алмыйлар иде. Кулланылышта булган башка гыйлемнәрдә алга киткән галимнәр исә «гыйлем-е кыйраәт» белән шөгыльләнергә вакыт таба алмыйлар иде. Бу сәбәптән әһле кыйраәт гыйлемнәрдән, әһле гыйлем кыйраәттән мәхрүм калалар иде. Гыйлемнәрдән өлешсез калган кыйраәт осталары ислам милләте күзендә игътибарсыз булып калды. Соңрак заманнарда «әһле кыйраәт» үзләре сайлаган юлларында чаманы югалтып, Коръән кыйраәтенә иге-чиге булмаган кадәр уйлап чыгарылган төрле алымнар өстәделәр. Шулай итеп, «гыйлем-е кыйраәт» авырлашканнан авырлаша барды. Нәтиҗәдә, кыйраәт гыйлеме кайбер ислам илләрендә бикләнеп калып, кайбер ислам илләрендә бөтенләй юкка чыкты. Бу заманда гыйлем-е кыйраәттә иң мәшһүр төбәк Мисыр төбәге иде. Алай булса да, анда кариләрнең[1] күбесе бар тырышлыкларын тик тәҗвид белән көйләп укуга багышлыйлар иде. Җиде яки ун кыйраәт рәвешләрендә белгеч булганнар гаять сирәк очрыйлар иде. Булса да, башка гыйлемнәрдә белемнәре аксый торган булды. Кыйраәт тарихы турында бәянымда хәзерге вакытта бу кадәре белән канәгатьләнеп торам.

---

[1] кари – Коръән уку остасы.

# «Йáҗүж» китабыннан[1]

## Ислам әсәрләрендә Йаҗүж

Хизкыял кебек нәбинең, Лаһути Йуханна язып калдырган мөкаддәс китапларның куәтле тәэсире белән Йаҗүж-Маҗүж дәһшәт мисалы, вәхшилек һәм ишлелек үрнәге булып, исламның әүвәлге гасырларына да мәгълүм иде.

Газафир исемле бай бер адәмнең олы юмартлыгы хакында мәшһүр шагыйрь Фараздак[2] бу бәетләрне әйткән:

(لعمرك ما الارزاق يوم اكتيالها باكثرخيرا من خوان العذافر)
(ولو ضافه الدجال يلتمس القرى وحل على خبازه بلعساكر)
(بعدة ياجوج وماجوج كلهم لاشبعهم عاما غداء العذافر)

Ягъни: «*Йáҗүҗ-Мáҗүҗ кадәр гаскәре белән дәҗҗал әгәр кунак булса иде, Газафирнең бары тик бер сабахлык тәгаме[3] убыр[4] Йáҗүҗ-Мáҗүҗләрне бер ел дәвамында туклandырып торыр кадәр булыр иде*».

Йáҗүж-Мáҗүжләрнең чүл дәрьяларындагы ком бөртекләре кадәр күп булуларын бик матур итеп файдаланган безнең

---

[1] Чыганак: Җаруллаһ, Муса. Коръән кәрим айәт кәримәләренең могъҗиз гыйбарәләренә күрә Йáҗүҗ. Берлин, 1933. Б.14–18. (Өзек татар теленә тәрҗемә ителде).

[2] Фараздак (әл-Фараздак; чын исеме – Хәммам бине Галиб; 641–728/730) – гарәп шагыйре Ислам дәверенең беренче гасырында иҗат итүенә карамастан Фараздак җаһилият дәверендәге гарәп шигърияте традицияләрен дәва иттергән һәм үзенең әсәрләрендә бәдәвиләрнең идеалларын һәм игелекләрен олылаган, үзенең кавемен һәм туган-тумачаларын мактаган, дошманнарны хурлаган. Шагыйрьнең мирасын туплаган тулы фәнни хезмәт әлегә кадәр юк. (Чыганак: Бакый углы Әнәс Хәлидов: http://feb-web.ru/feb/kle/kle-abc/ke7/ke7–8952.htm).

[3] сабахлык тәгам – иртәнге аш.

[4] убыр – күп ашаучы; туймас тамак.

гарәп шагыйре яһүдләрнең бөек хыялларына да көлеп кенә караган гүзәл бер бәет әйткән иде.

Үз заманының бөтен голүмләрен туплаган «Ихван әс-сафа» мәҗмугасы географиягә караган 4 нче рисаләдә: (الاقليم السابع بلاد ياجوج وماجوج والبلغار والصقالبه)[1] дигәннән соң, 8 нче рисаләдә: (ياجوج و ماجوج من وراء السد هما امتان صورتهما آدمية ونفوسهما سبعية لا تعرفان التدبير ولا السياسة لا تعرفان الا صيد السباع و الا النهب و الغارات بعضها لى البعض ويأكل بعضها البعض)[2] – диелгән.

Төркестан төрекләре, Болгар мөселманнары, рус славяннары хакында гыйлем мәҗмугаларының соң дәрәҗәдәге наданлыкларын күр! Насараларның борынгы хариталары, яһүдләрнең юк-бар әкиятләре асыл чыганак булганнан соң, мондый бәяннар акылга сыймаслык бер нәрсә булмаса да, насараларның, яһүдләрнең Гугларын, Магугларын Коръән кәрим айәт кәримәләреннән өстен күрү, әлбәттә, һич акылга сыя торган нәрсә түгел.

«Кәшеф әз-зонүн»[3] кебек мөһим бөек бер китапның мөҗтәһид мөхәкъкак[4] төзүчесе төрек «Җиһаннамә»[5] кебек

---

[1] Тәрҗемәсе: «Җиденче яшәеш даирәсе Йáҗүҗ-Мáҗүҗ, болгар һәм сәкалибә илләредер».

[2] Тәрҗемәсе: «Йаҗүҗ-маҗүҗ Сәдд артындадыр: алар адәм кыяфәтенә ия булган ике өммәттер; икесенең дә табигатьләре вәхшидер. Алар ни хуҗалык итүне белмиләр, ни сәясәтне. Кыргый хайван аулау, талау һәм бер-берсен алдаудан башканы белмиләр. Алар бер-берсен ашыйлар».

[3] «Кәшеф әз-зонүн» – XVII йөзьеллыкта Госманлы дәүләтенең фикри тормышында зур урын алган Кятиб Чәләбинең (милади 1657-дә вафат) әсәре. Егерме ел дәвамында әзерләнгән бу күләмле библиографик һәм фәнни энциклопедия гарәп телендә язылган. Аның беренче исеме «Китаб иҗмагъ әл-фусуль вә-л-әбваб фи тәртиб әл-голүм вә әсма әл-китаб» була. Китапка төзәтмәләр кертеп, аны тулыландырганнан соң, Чәләби аның исемен «Кәшеф әз-зонүн ган әсами әл-күтүб вә-л-фөнүн» итеп үзгәртә.

[4] мөхәкъкак – чын, хакыйкый; хаклыгы (дөреслеге) мәгълүм булган.

[5] «Җиһаннамә» – Госманлы дәүләтенең беренче систематик география китабы. Югарыда искә алынган Кятиб Чәләбинең әсәре.

гаять яхшы бер китабында татар, төрек, Йáҗүҗ-Мáҗүҗ хакында, 316нче сәхифәләрендә болай дип язган:

«*Ул кавем бәни Адәм арасында корыч табигать иясeдер. Су белән җил кебек. Табигатьләре хәрәкәткә күнеккән. Куәте җеннеке, токымы диюнеке. Атлары ни куәт эстәр, ни азык. Ау-сунар бакчаларында агач уклары нәрсәгә кадалса, шуны ашарлар, чүлдәге дөя кебек ашыйлар. Ни үзләре арымыйлар, ни дә атлары тирләп чыгар. Атландыклары атка ни дага кирәк, ни кадак. Ашаячаклары иткә ни казан кирәк, ни сих*[1]. *Дәрьяларда сәяхәт итәләр, ни көймәче эзләрләр, ни көймә. Сахраларда сәяхәт итәрләр, ни су йөртерләр, ни ат җиме. Үзләре тауларда яши торган куркусыз бүреләр кебек, әмма сарык тиреләре киеп йөриләр. Корт вә кошның, каз-киекнең һичберен аерып тормыйлар, үлеләрен дә, тереләрен дә ашыйлар. Акылдан язганнар кебек. Тәннәренең вакыт узуында кайгысы юк. Тешләре коелып авызлары сәдәф эче*[2] *кебек шома булып калуны, яки көзге сары яфрак кебек йөзләренең саргаюын белмиләр. Атлап йөрешләре шөһрәт белән. Ай кебек, кояш кебек күзләренең нуры сүнмәс. Биш йөз мең гасырлык күк йөзе кебек билләре бөгелмәс. Йөз яшендә дә кылыч кебек балкып торган йөзлеләр. Күзьяшенең ни икәнен белмәгән күзләре укның тимер очлыгы кебек җитездер. Энҗе кебек күзләре гаять кечкенә. Калкан кебек йөзләре гаять зур. Кызыл тәннәренең ныклыгы, әйтерсең лә, бер кыя. Башлары мәһабәтлек сахрасында бигрәк тә зур. Бу сүзләрнең раслануы:* (اتركوا الترك ما تركوكم). *Ягъни: «төрекләр сезгә кагылмаган, сезнең белән сугышмаган чакта, сез аларга орына күрмәгез». Гаять куәтле, тәмам мәрхәмәтсез, вәхши бер таифәдер. Телләре төркидер* (توركى). *Йолалары да аларга якындыр. Сугышларга хатыннары белән бәрабәр чыгалар. Диңгездан кала башка хайваннарны ашыйлар. Йáҗүҗ-Мáҗүҗ төректер* (توركدر). *Җирнең кешеләр яши торган иң ерак кыйтгасында яши торган кавемдер. Нәселләре бик бәрәкәтледер. Саннары чиктән ашкан. Тирә якка җәелделәр, халык тормышын бозып*

[1] сих – шиш, шампур.

[2] сәдәф авызы – бака кашыгының эче.

*бетерделәр. Зөлкарнәен ул якларга барганда, халык шикаять итте. Тауларны бер аралык аша кичәрләр иде. Юл шул аралык аша гына иде. Искәндәр ул аралыкны томалады. Бөек бер дивар (сәдд) төзеде*».

Татар-төрек, Йа́җүҗ-Ма́җүҗ, Сәдд-е Искәндәр[1] хакында ислам әсәрләрендә язылганнарның кыскачасы будыр.

Гаскәрләрен һәрвакыт һәр җирдә дошман исәбенә тукландыра торган төрекләр хакында «Җиһаннамә» бәяны һәм Зөлкарнәеннең җирле халык белән корган килешүенә күрә дә, һәм Һуннар[2] дәверенә күрә дә, һәм Чернгиз[3] (چنگیز), Тимур[4] (تیمور) кебек олуг җиһангирләрнең гасырларына күрә дә, әлбәттә, тулысынча дөрес була ала. Ләкин, андый олуг җиңүләргә ирешүнең чараларын шул кадәр яхшы күрә алган төрек кумандannары[5], яһүд кяһиннәре яки насарaният чиркүәләрендә бикләнеп тарих китаплары язган тарихчыларның хыялларындагы кебек, шул кадәр вәхши була алмыйлар. Егерменче гасырның бөек мәдәниятләрен, бүгенге җиһан мөхарәбәләрен, большевизм инкыйлабларын күргәннән соң, фараз итик, шулайдыр. Яһүдләрнең, насараларның Гугларын, Магугларын Коръән кәрим Йа́җүҗе белән, Ма́җүҗе белән бер

---

[1] Сәдд-е Искәндәр – Искәндәр дивары

[2] Һуннар – безнең эраның 370 нче елларында Идел-Урал буйларыннан китеп, Көнчыгыш Аурупаны яулап алган төрки телле халык. Атилла хан идарә иткән дәвердә (434–453) һуннар иле көнчыгышта Җаек буйларыннан башлап көнбатышта хәзерге Франция чикләренә кадәр сузылган була.

[3] Ченгиз (Чыңгыз хан, м. 1227 вафат) – дөнья тарихында иң зур: Тын океаннан Идел буйларына кадәр сузылган – төрки дәүләткә нигез салучы ил башы (хан, каһан), җиһангир яугир.

[4] Тимур (Тимер ләңг, Әмир Тимер, 1336–1405) – әмир дәрәҗәсен йөрткән ил башы, җиһангир яугир, үз вакытында Урта Азия, Көньяк Азия, Көнбатыш Азияләрнең, Кавказ, Идел буе һәм Русиянең сәяси тарихына зур йогынты ясаган кеше. Үз эченә Иран җирләрен, Кавказ, Сүрия, Гыйрак, Әфганстан, хәзерге заманда Пакьстан дип аталган илнең бер өлешен алган зур дәүләт төзеп калган.

[5] кумандан – хәрби җитәкче; командир.

итеп күреп, ислам әсәрләренең бәяннарына канәгать итик тә, Йáҗүҗ-Мáҗүҗ төрекдер, татардыр, диик.

## Әгәр Йаҗүҗ төрек булса

Йаҗүҗне төректер дип фараз кыйлсак, бүген Зөлкарнәйн төзегән диварның инде юклыгыннан башларга тиеш булачакбыз. Һуннарның бөек куәтләре белән ул дивар күптәннән инде җимерелеп ташланган. Һуннарның исламга кадәрге дәһшәтле дәвамлы яулары бары тик кечкенә Филистыйн җирләрен түгел, бәлки бөтен җир йөзен дә кан туфаннары белән сугарганнар иде. Ченгиз (چنگیز) яулары белән дә Йáҗүҗ-Мáҗүҗ турындагы хәбәрләр мең дә бер мисал белән расланган[1]. Мәдинәт әс-сәлам[2] фаҗигасе да, Һулакү[3] (هلاكو) вакыйгасы да, Лаһути Йуханнаның хыялында күргән руялары биш-ун кадәр мисалы белән белдергән, Хизкыял кебек нәбиләрнең хәбәрләрен дә Ченгиз-Һулакү кыямнары артыгы белән раслаган. Болай булгач, кыямәт якынайган дәвердә Йáҗүҗ-Мáҗүҗ фетнәләренең янә бер мәртәбә күтәрелүе өчен моннан соң инде мөмкинлек калмаган.

Ислам нуры белән Йáҗүҗ-Мáҗүҗ куәтләре тәмам җиңелгәннән соң, ягъни җир йөзенең бөтен төрекләре-татарлары исламны кабул иткәннән соң, Йáҗүҗ-Мáҗүҗ мәсьәләләре дә хәл кыйлынган булып чыга, Йáҗүҗ фетнәләре дә бетерелгән булып чыга.

Әгәр Йáҗүҗ төрек булса иде, ягъни төрекләрнең ана йортларына Гугъ Магугъ исемнәрен үз белдекләре белән таккан яһүдләрнең, насараларның башларындагы хыялларының, күзләренә күренгән руяларның, мәкерле аңлатуларының

[1] Игътибар ителәсе нәрсә: Муса әфәнденең язганнарына күрә, ул һуннарны да, Ченгиз-Һулакүләрне дә төркиләрдән санаган һәм һич тә монгол-фәләннәр дип язмаган.

[2] Мәдинәт әс-сәлам – Бәгъдад шәһәренең шигъри исеме (Сүрия).

[3] Һулакү (1217–1265) – татар яугире, ил ханы, Чыңгыз ханның оныгы. Якын Шәрыкны яуларга чыккан татар чирүенең башында тора. 1256–1260 елларда Иранны, Гыйракны һәм аларның янәшәсендәге илләрне яулап ала. 1258 елда Габбаси хилафәтен тар-мар итә, Бәгъдад шәһәрен ала.

Коръән кәрим айәт кәримәләреннән өстен origin ителүләре бөтен кыенлыклардан иң зур кыенлык булмаса иде, бу очракта безгә нисбәтән Йа́җүҗ-Ма́җүҗ мәсьәләләре хәл ителгән була алыр иде.

Әмма Коръән кәрим айәт кәримәләренең болай хәл ителүләре белән дә канәгатьләнсәгез, Мәккә тауларында һәляк кыйлынган Әсхаб-е фил[1] кебек, я аннан да дәһшәтлерәк сурәтләрдә көннәрнең берсендә Филистыйн тауларында бөтен төрекләрнең харап ителәчәкләренә дә ышану сезнең мантыйгыгызның котылгысыз бер нәтиҗәсе булып калачак (12 с. 7 ракым)[2].

Коръән кәримнең бөеклеге һәм изгелеге хозурында мондый нәрсәләрнең хәтта әйтелүләреннән дә, хәтта аңлатылуларыннан да мин ерак торырга тырышам. Әгәр Коръән кәримдә искә алынган Йа́җүҗ-Ма́җүҗ яһүдләрнең, насараларның Гугъларыннан-Магугъларыннан гыйбарәт булса иде, бу очракта Коръән кәрим үзе үк яһүдләрнең вак-төяк күзгә күренмеш руяларыннан, ялган хыялларыннан оештырылган кечкенә генә бер интихаль[3] булып калыр иде.

Йа́җүҗ мәсьәләсендә мине бу кадәр интектергән дүртбиш кыенлыкны, югарыда 4–6 нчы сәхифәләрдә үз карашларымның нигезләрен бәян иткәндә, тәфсилләп аңлаткан идем. Тагын да зуррак булган кыенлыкны әлеге ике-өч сәхифәдә сезнең игътибарыгызга тәкъдим иттем. Бөтен бу кыенлыклар башымны да, йөрәгемне дә газаплыйлар иде. Еллар дәвамында көчле бәргәләнүләр, интегүләр эчендә калдым. Нәтиҗәдә, Коръән кәримнең «йа́» кисәкчәсе мине бу халәттән азат итте: самиләрнең кечкенә һәм зур китапларына хәлиткеч юл күрсәткече, гаҗәеп дәрәҗәдә файдалы күрсәтмә

[1] Әсхаб-е фил («Фил ияләре») – Мөхәммәт пәйгамбәрнең туган елында Мәккәне яулап алыр өчен килгән яуның исеме. Ул чирүдә сугыш филе булганга күрә, аны «Фил явы» дип тә, «Фил ияләре» дип тә атаганнар.

[2] Автор югарыда 12 нче сәхифәдәге 7 нче маддәдә Лаһути Йуханнаның күзенә күренгән руялары нигезендә язылган юрауларга ишарә итә.

[3] интихаль – үзләштерү; плагиат.

буларак, «Гаһед гатыйкъ»ның «җүҗ»»ләренә Коръән кәримдә өстәлгән «йá» кисәкчәсе кыенлыкларның зурырысыннан да, кечесеннән дә мине тәмам азат итте. Шаригъ хәким, нәби кәрим[1] өмми[2] Мөхәммәт, галәйһис-саләт вә-с-сәлам, хәзрәтләре кебек укый-яза белмәгән берәү Коръән кәримдәге мондый бәрәкәтле «йá»нең, шул кадәр җиңел, шул кадәр гаҗәеп дәрәҗәдә файдалы гүзәл игъҗазның[3] шаһиты булды. Өммәтне җитәкләүче имамнарның иҗтиһадларына иярү әдәбе аркасында, гыйлем эстәү юлларыннан тайпылмавымның бәрәкәте белән, Коръән кәримдә өстәлгән «йá» кисәкчәсенең нуры белән мәсьәләнең хәл ителүе сахилләренә[4] ирештем. Гыйлем эстәү юлларында, кимендә, минем кадәр, яки аннан да артык иҗтиһад иттерү хакындагы килешү белән, максатчан төрек шәкертләренә бу китабымны шөкеранә кулы белән тәкъдим иттем.

---

[1] Шаригъ хәким, нәби кәрим – хикмәт иясе булган шәригатьче, игелекле пәйгамбәр.

[2] өмми – укый-яза белми торган кеше.

[3] игъҗаз – Коръән кәримнең илаһи сүз булуын раслый торган һәм башка һичкем тарафыннан кабатлана алмый торган һәм акылга сыймаслык дәрәҗәдә могъҗизави төзелеше.

[4] сахил – су буе, диңгез буе; биредә – иркенлек.

# «Хатун» китабыннан[1]

## Ханымнарга ихтирам белдерү йөзеннән

Коръән кәримнән алган тәрбиям бәрәкәте белән хатын-кызларның һәрберен, һәрвакыт ихтирам итә идем, һәрвакыт ихтирам итәмен. Аеруча Расүл кәрим[2], Шаригъхәким Мөхәммәд галәйһи-с-саләтү вә-с-сәламү хәзрәтләренең әнкәсе Әминә Хатун[3] Ваһһабия хәзрәтләре (1); ятим Мөхәммәднең сөт анасы Хәлимә Сәгъдия (2) хәзрәтләре белән, Сөвайбә Ләһһабия җәнабләре (3); яшь бала чагында багучылары булып, гомеренең соңгы елларына кадәр хөрмәтле хадимәләре[4] булу мәртәбәләренә ирешкән Әймән Бәракә Хәбашия ханым хәзрәтләре (4); малы белән, кямиллеге белән, акылы белән, бөтен куәте белән Шаригъ хәким хәзрәтләрен тулысынча тәэмин итеп, Рисаләтнең[5] иң бөек вазифаларын үтәү юнәлешендә егерме биш еллык хәят рафикасы[6], гаилә тәрбиячесе, Ханә-и сәгадәтнең[7] хуҗабикәсе, Нәсел-е рисаләт[8] анасы булу бәхетләренә ия булган сәййидә[9] Хәдиҗә, галәй-

[1] Чыганак: Җаруллаһ, Муса. *Корьән кәрим айәт кәримәләре нурлары хозурында хатун.* Берлин, 1933. Б. 6–18. (Өзек татар теленә тәрҗемә ителде).

[2] Расүл кәрим – Кадерле илче – Мөхәммәд пәйгамбәр салләллаһу галәйһи вә сәлләмне хөрмәтләп телгә алу гыйбарәсе.

[3] хатун – госманлы дәүләтендә һәм төрки халыкларда абруйлы мөхтәрәм хатын-кызны белдерә торган сүз.

[4] хадимә – хезмәтче ханым.

[5] рисаләт – Мөхәммәд салләллаһу галәйһи вә сәлләмнең расүллек кыйлуы; Аллаһтан җибәрелгән илче (расүл) вазифаларын үтәү.

[6] хәят рафикасы – тормыш иптәше.

[7] Ханә-и сәгадәт – Бәхет йорты, ягъни, Мөхәммәд пәйгамбәр салләллаһу галәйһи вә сәлләмнең гаиләсе белән торган йорты.

[8] Нәсел-е рисаләт – Расүлнең (расүлләрнең) нәселе.

[9] Авыш хәрефләр белән язылган сүзләрнең аңлатмасы китапның

һи вә галәйһа әс-саләт вә-с-сәлам, хәзрәтләре (5); Мәдинәдә яшәгән дәверендә Рисаләт-ханәсенең[1] иң сөекле сәййидәсе, иң олы сәгадәте буларак, торган бүлмәсе бөтен вәхиләрнең[2] иңгән урыны булып, Рисаләтнең бөтен минутларының шаһиты ителү бәрәкәте белән, әсхаб-е китапның[3] һәрбереннән артыграк сурәттә нөбүввәт голүмнәрен[4] һәм сәхабәләргә,[5] һәм ислам мөҗтәһидләренә тапшырган Өмме-л-мөэминин[6], мөҗтаһидләрнең әйдәп баручысы сәййидә садыйка[7] Гайшә Бәкерия (6) хәзрәтләре белән бергә, бөтен Өммәһат әл-мөэминин хәзрәтләре (7); ислам милләтләренең кыз балалары өчен бөек мисал, хәтта идеал буларак Сәййиде-л-әнбия[8] хәзрәтләренең Сәгадәт-ханәләрендә тәрбия кыйлынмыш кәримәләре[9]: Зәйнәб, Рокыя, Өмм-е Көлсем, Фатыйма (Имамә, Рокыя, Зәйнәб, Өмм-е Көлсем) хәзрәтләре (8), бу бөек сәййидәләрнең бөтен исламият, бәлки кешелек дөньясына нисбәтән бөек хөрмәтләренең нуры белән; ниһаять, барлыгымны, өлешләп тә, бөте-

ахырында урнаштырылган сүзлекчәдә.

[1] Рисаләтханә – расүллек йорты; пәйгамбәрнең йорты.

[2] вәхи – Аллаһ тарафыннан пәйгамбәрнең күңеленә иңдерелгән илаһи хәбәр, илаһи белем; Коръән айәтләре.

[3] әсхаб-е китап – күктән иңгән изге язмаларга (китапларга) ия булган халыклар.

[4] нөбүввәт голүмнәре – пәйгамбәрнең өйрәтеп калдырганнары; пәйгамбәрлеккә караган белем.

[5] сәхабәләр – Мөхәммәд пәйгамбәр салләллаһу галәйһи вә сәлләмнең иярченнәре, аны үз күзләре белән күргән, аралашкан беренче буын мөселманнар.

[6] Өмме-л-мөэминин (күпл.санда: Өммәһат әл-мөэминин) – ягъни Мөэминнәрнең анасы; Мөхәммәд пәйгамбәр салләллаһу галәйһи вә сәлләм хатыннарының шәрәфле исемнәре. Коръәндә мөселманнарга үз аналарын тормышка алу тыелганга күрә, пәйгамбәрнең хатыннарын «мөэминнәрнең аналары» буларак тану аларның пәйгамбәрдән соң кабат кияүгә чыгуларына Аллаһ тарафыннан куелган киртә булган.

[7] садыйка – турылыклы, ышанычлы, әманәтле ханым.

[8] Сәййиде-л-әнбия – ягъни Пәйгамбәрләрнең әфәндесе; Мөхәммәд пәйгамбәр салләллаһу галәйһи вә сәлләмнең мәртәбәле исеме

[9] кәримәләре – кызлары.

не белән дә бөтен тормышымны миңа бүләк иткән вәлидәм[1] Фатыйма ханым Хәбиб хәзрәтләренең миңа кагылышлы иң олы хөрмәтләренең яктысы белән, иман рухы белән, басыйрат күзе[2] белән багып аларның һәрберен ихтирам итәм. Хатын-кызларга карата булган ихтирамым, әйткәнемчә, Коръән кәрим тәрбиясе белән миңа сеңгән әдәптер.

Минем өчен хатын-кыз ул: 1) минем үз анамдыр, дәү әниемдер; 2) минем кыз туганымдыр, анам-атамның кыз туганнарыдыр; 3) тормыш иптәшем, балаларымның анасы сәййидәмдер; 4) ниһаять, хатын-кыз – ул минем кызларым. Ягъни, диннәрнең әмере белән дә, табигатьнең хикмәте белән дә, иҗтимагый низамның куәте белән дә, хатын-кызларның һәрберен һәрнинди хәлдә ихтирам итү минем, әлбәттә, олы вазифамдыр.

Дәүләтләрнең, өммәтләрнең иң асыл башлангычы – гаиләдер. Дәүләтләр, өммәтләр гаиләләрдән гыйбарәт булалар. Гаилә ике асыл терәктән: 1) хатыннан; 2) бер ирдән башлана. Бу ике асыл рөкенның үзара мәхәббәте, бер-беренә карата мәрхәмәте булмаса, гаиләдә бәхет булмый. Ирләрнең куәтләре бәрабәренә хатын-кызларның гаиләдә хөрмәт ителүләре тәэмин ителмәсә, гаилә нык булмый. Гаилә нык булмаса, дәүләт көчле булмый, өммәт куәтле булмый. Болар «ике икең – дүрт» кебек катгый бер хакыйкатьтер.

Гаҗәп хәл, кеше әллә никадәр ераклыктагы билгеле булмаган нәрсәләрне ача, ләкин иң якын нәрсәләрне белми. Адәм баласы ахыры-чиге булмаган галәмнең әллә кайсы тарафларында булган иң ерактагы күк җисемнәре турында, андагы сәер хәлләр турында белә: кеше иң зур күк җисемнәренең авырлыгын граммнарына кадәр үлчәп билгели; иң кечкенә матдә берәмлекләрен электроннарына кадәр тикшереп тасвирлый. Кеше үзенә бирелгән тәю әгъзаларының мөмкинлекләреннән тышта булган әллә нинди яшерен хакыйкатьләрне ачып өйрәнә. Ләкин үзенә иң якын нәрсәләрне белми: кеше

[1] вәлидәм – әнкәм.

[2] басыйрат күзе – әйберләрнең, күренешләрнең асылын күрә торган караш.

кешене аңламый; үзенә зарар китерә торган нәрсәләрне – файдалы нәрсәләрдән, начарларын яхшыларыннан аера белми. Җир йөзендә мәдәният меңнәрчә гасырлар буе дәвам итеп килсә дә, сәяси, иҗтимагый, әдәби[1], әхлакый мәсьәләләрнең күбесен мәдәни инсан[2], әле һаман да, хәл итә алмый. Инде иң ерак кяъинәтнең[3] дә төзелеше турында хәбәрдар булган кеше өендә, гаиләдә бәхетле тормыш кору турында берни дә белми. Нидән болай бу?

Кешенең ихтыяры вә акылы азат булганда, ул белмәгән нәрсәләренең барысын да ача ала. Ә инде, я акылы, я ихтыяры чикләүләрнең берсе белән киртәләнгән булса, кеше хәтта мәгълүм мәсьәләләрне дә аңлый алмый.

Риязый[4], табигый мәсъәләләр турында сүз йөрткәндә, аның фикере кяъинәтнең иң ерак өлкәләренә хәрәкәт иткәндә, кеше ниятенең дөрес булуы, калебенең ихлас булуы, уйларының саф булуы, хисләренең сәламәт булуы, ихтыярының ирекле булуы шарт. Мәгълүм ки, күкләргә бары тик шундый кешеләр аша, ачыш юлларына бары тик шундый кешеләр чыга. Ләкин җир йөзенең хәлләре белән шөгыльләнгәндә; иҗтимагый, сәяси, милли мәсьәләләр турында укыганда, аларны өйрәнгәндә; нәфсаният[5] кебек, тәкәббер[6] кебек, хирыс[7], шәһвәт, дошманлашу, үч алу кебек, куәтле пәрдәләр кешеләрнең йөрәкләрендә, акылларында, хисләрендә баш күтәрә. Кеше шул чакта иң ачык хакыйкатьне дә, иң файдалы мәсълихәтне дә күрә алмый. Яки, белә торып, күрә торып, начар нәрсәләрне сайлап ала; бозык-

[1] әдәби – биредә әдәп даирәсенә караган мәсьәләләр күздә тотыла; әдәбият (литература) сүзе дә кешене әдәпкә өйрәтә торган нәфис сәнгать төрен белдерә; бу йөздән, әдәби мәсьәлә һәм әдәбият мәсьәләсе икесе ике нәрсә булып тора.

[2] мәдәни инсан – мәдәният эчендә яшәүче кеше; цивилизацияле кеше.

[3] кяъинәт – космос.

[4] риязый – математикага караган нәрсәләр; (математический).

[5] нәфсаният – эгоизм.

[6] тәкәббер – олылану, борын күтәрү; үз-үзеңне әлләкем дип белү; масаю.

[7] хирыс – комсызлык; нәрсәнең булса да иясе булырга теләү.

лык юлларына кереп китә. Кыскасы, сәяси, иҗтимагый, әдәби, икътисади мәсьәләләрдә кешеләрнең акыллары да, ихтыярлары да, зәгыйфь яки куәтле һаваланулары тарафыннан, вак-төяк хиссиятләре тарафыннан җиңелә.

(و حفظناها من كل شيطان رجيم)[1] (15:17). «Күкләрдә шайтан юк. Ләкин кешеләрнең кан тамырларында шайтан кан кебек ага», дигән мәшһүр сүзнең мәгънәсе будыр. <…>

Ислам фикъһысы буенча язылган китапларда хатын-кызларга кагылышлы хөкемнәр[2] даирәсендә мәзһәбләр арасында азмы-күпме каршылыклар булса да, хатын-кызлар мәсьәләсе хакында безнең фәкыйһләрнең уй-фикерләре бөтенләй юк иде. Тик шушы заманда гына мөҗтәһид Касыйм Әмин[3] хәзрәтләренең «*Тәхрир әл-мәръа*»[4] исемле гаять гүзәл әсәренең бөек бәрәкәте белән, Мисырда, Һиндыстанда, Төркиядә, Русиядә хатын-кызлар мәсьәләсе хакында йөзләрчә әсәрләр, мәкаләләр нәшер кыйлынып, гүзәл бер фикер хәятенең[5] эзләре бервакыт күзгә күренә башладылар. Ләкин ул әсәрләрнең, ул мәкаләләрнең күбесе я хиҗаб[6], я сөфүр[7] мәсьәләләре белән генә чикләнеп калып; хатын-кызларның яратылыш ягыннан да, акыл ягыннан да җитешсезлекләре турында, фет-

---

[1] «Һәм аны [күкне] куылучы шайтанның һәммәсеннән сакладык» (Коръән, 15:17).

[2] никях, талак, мирас бүлү, хатын-кыз гыйбадәтенең үзенчәлекләре, аның өртүле булуы кебек мәсьәләләр.

[3] Касыйм Әмин (1865–1908) – Фәрангистанда (Франциядә) белем алган мисырлы хокук белгече, әдип, публицист, фәлсәфәче, сәясәтче һәм җәмәгать эшлеклесе; Мисыр халкының милли хәрәкәтен башлаучыларның, Каһирә университетына нигез салучыларның берсе; мөслимәләрнең хокукларын яклаучы.

[4] «Тәхрир әл-мәръа» («Хатын-кызны азат итү», 1899 ел).

[5] хәят – яшәеш, тормыш.

[6] хиҗаб – Коръәндә хиҗаб төшенчәсе бүлмәнең бер өлешен икенчесеннән аера торган чаршау мәгънәсендә һәм матди булмаган, ягъни нәрсәне дә булса икегә бүлә торган күзгә күренмәс чик мәгънәсендә кулланыла; сүзлекләрдә чаршау, япма, ябынча, бөркәнчек мәгънәләрендә килә.

[7] сөфүр – битнең ачык булуы; хатын-кыз йөзенең өртүсезлеге.

нәдән курку кебек шикләнүләрдән гайрәтләнеп, кыза-кыза бәхәсләшәләр иде. Мин бу мәсьәлә белән кызыксынганыма күрә, андый әсәрләренең һәрберен укыдым. «*Әл-Фөтүхат әл-Мәккиййә*»[1]нең беренче томында (احرام المرأة فى وجهها)[2] исемле бүлектә хиҗаб мәсьәләсе тәмам җиренә җиткерелеп хәл кыйлынган булса да, укыган әсәрләрнең һичберендә «*Фөтүхат*»тәге ул гүзәл бәяннарын күрмәдем.

Пәрдә генә булмыйча, хатын-кыз йөзенең матур бер зиннәте[3] кебек бер нәрсә булып калган хиҗаб Мисыр[4], Хиҗаз[5] кебек җирләрдә йөздә нибары биш-ун[6] кадәр аз, яки тәмам юк кебек иде исә дә, хиҗаб мәсьәләләрендә һичбер кыйммәте булмаган көчле бәхәсләр соңгы көннәргә кадәр гарәп матбугатында дәвам итте. Хиҗаб турындагы фикер алышуларның ханымнар карашында бүген әһәмияте калмаган кебек үк, бүгенге шәкеле белән хиҗабның да әхлакый тормышта иҗтимагый кыйммәте калмаган. Шулай да, бәхәсләшүчеләрнең сүзләрендә, фикерләрендә мөселман ханымнарын гаепләү гыйбарәләре, яки шуңа ишарәләре булмаса иде, ике тарафның һәрберен – хиҗаб тарафдарларын, да сөфүр тарафдарларын да – мин аңлый да, аклый да алыр идем. Берсе – милли гадәт, Шәрыкнең бер гадәте буларак горурлык галәмәте[7]; икенчесе Гаребнең мәдәни гадәте буларак, мәдәният дөньясының модасы, хатын-кызларның табигый хокукларының билгесе булыр иде.

[1] «Әл-Фөтүхат әл-Мәккиййә» – урта гасыр мөселман галиме, суфыйчылыкның күренекле вәкиле ибне әл-Гарәби (1165–1240) хәзрәтләренең иң танылган дини-мистик эчтәлекле әсәре.

[2] «Ихрам аль-мар’а фи ваджхиха» – хатын-кызның ихрамы аның йөзендәдер (ихрам (гарәп.) – тар мәгънәдә хаҗ кыйлучылар кия торган махсус кием, киң мәгънәдә – әхлаклылык, сафлык).

[3] зиннәт – бизәк; матурлык өстәүче.

[4] Мисыр – Египет.

[5] Хиҗаз – Гарәп ярымутравының Кызыл диңгез буйлап сузылган тарихи төбәге; үз эченә Мәккә белән Мәдинә шәһәрләрен дә ала.

[6] йөздә нибары биш-ун – 100 дә нибары 5–10, ягъни 5–10%.

[7] галәмәт – билге, күрсәткеч; тамга.

Хатын-кызларның җәмгыятьтә хөрмәт ителүләре өммәтнең иманы белән, дәүләтнең кануны белән, гомуми әдәп куәте белән тәэмин кыйлынган булса иде, ни хиҗаб кирәк булыр иде, ни сөфүр фетнә булыр иде. Ханым вә туташларның иҗтимагый кадер-дәрәҗәләре булмый торып, ни йөз пәрдәсенең файдасы юк, ни дә сөфүрнең артык зарары юк.

Йөз пәрдәсе гыйсмәт[1] билгесе буларак хатын-кызларның үз ихтыярлары белән кабул кыйлынган булса иде, бүген хиҗаб дәүләтнең бәйсезлек байрагына тиң *мөкаддәс* бер байрак булыр иде. Мәгълүмдер, куәт булмаса, яки дошманның куәте зуррак булса, дәүләтнең байрагы дошман аяклары астына атылып таптала. Бәйсезлек байрагы буларак изгелеге булмаса – байрак; сафлык байрагы буларак изгелеге булмаса – йөз пәрдәсе: икесе дә һич булыр[2].

Нәби кәрим Расүл рәхим[3], Шаригъ хәким Мөхәммәд, галәйһи-с-саләтү вә-с-сәлам, хәзрәтләре боерганнар иде: (لتقتلن بعذراء امة),– дип, ягъни *әгәр өммәт үзенең кәримәләрен химая[4] юлында җан бирергә әзер булмаса, ахырда ул өммәт дошман кулыннан харап була*. Җәмгыятьтә ханымнарның, туташларның хөрмәтле, кадерле булулары өммәтнең яшәеше димәктер. Хатын-кызларга карата ихтирам булмаса, яки аларның хөрмәтле затлар булуы өммәтнең куәте белән сакланылмаса, андый өммәттә тереклек тә булмаячак.

Безнең Шәрыкта хиҗабның исеме булса да, ханымнарга, туташларга карата хөрмәт бүген аз. Соңгы елларда Шәрыкта вак-төяк фетнәләрнең дәһшәтле фаҗигаләре арасында хатын-кызларның, өммәт аналарының никадәр кадерсез, никадәр хөрмәтсез булулары гаять вәхши сурәтләрдә күренде. Йөз пәрдәсенең әхлакый файдасы булмаса да, иҗтимагый кыйммәте бүген тәмам калмаган булса да, хатын-кызларның хөрмәтле булулары өммәтнең тереклеге генә түгел, милләт-

---

[1] гыйсмәт – сафлык, намуслылык.

[2] һич булыр – берни булмас; юк булыр; булмас; юк.

[3] Расүл рәхим – кадерле илче; Мөхәммәд пәйгамбәр салләллаһу галәйһи вә сәлләмне хөрмәтләп телгә алу гыйбарәсе.

[4] химая – саклау, яклау.

нең башка халыклар арасында дәрәҗәседер, мәртәбәседер. Өммәтнең хатын-кызы, өендә булсын, тышта булсын, кимсетелгән, кыерсытылган булса, андый өммәткә карата хөрмәт вә ихтирам калмас.

Хатын-кызлар хакында Шәрыкта гасырларча дәвам итмеш мондый бер хәлнең сәбәпләре арасында сәмави[1] диннәрнең берсе дә, аерым алганда, ислам дине булмаса да, җәмгыятьне өйрәнүче галимнәрнең күбесе, милли юлбашчыларның бөекләре, мондый хәлләрнең сәбәпләрен ислам дине тәгълимнәрендә[2] күрәләр иде. Хаклары да, гозерләре[3] дә, әлбәттә, бардыр. Бөек җиһан сугышының якында барлыкка киләчәк нәтиҗәләре ачык күренгәннән соң, 1917 нче ел инкыйлаблары[4] гарәфәсендә[5] Русиядә дүрт-биш китап нәшер итеп, «*Шәригать әсасләре*» исемле китабымда хатын-кызларның хөрмәтләре, хокуклары хакында ун сәхифә язган идем. 40 нчы сәхифәдә: «мәдәни, иҗтимагый, сәяси, дини, әдәби хокукларның һәрберен хатын-кызларның һәрберенә ислам шәригате тулысынча, иң кямил сурәттә тапшырды»,– дигән идем. <…>

Гаребнең соңгы заман әдәбиятларында Хәүва кызларына[6] карата «җенес җәмил»[7], «җенес ләтыйф»[8] дип әйтү кебек купшы гыйбарәләр таралып китсә дә, Шәрыкның борынгы һәм яңа әдәбиятларында өй бикәләренә, гаилә аналарына, ата-

---

[1] сәмави – күкнеке; күктән килгән.

[2] тәгълим – өйрәтү; тәгълимат.

[3] гозер – сылтау; нинди дә булса эш эшләгәне өчен кешенең үз-үзен акларлык сәбәп.

[4] инкыйлап – асты-өскә килү; революция.

[5] гарәфә – зөлхиҗҗә аеның 9 нчы көнендә хаҗиларның Гарәфә тавында җыелып үткәрә торган хаҗ йоласы (Гарәфәт көне); Муса әфәнде бу сүзне инкыйлабка нисбәттән кулланганда, аның Аллаһтан бирелгән сынау яки җәза булуын күздә тоткан булса кирәк.

[6] Хәүва кызлары – хатын-кызлар; Муса әфәнде хатын-кызларны Адәм галәйһис-сәламнең хәлал җефетенең исеме Хәүва (гарәпчәсе حوَّاءُ булганга күрә һава (هواء) сүзе белән бутарга ярамый) булганлыктан шулай атаган.

[7] «җенес җәмил» – гүзәл җенес.

[8] «җенес ләтыйф» – нәфис җенес.

ларның рафикаларына[1] ихтирам белдерү гыйбарәсе буларак борынгыдан ук нәкъ менә *хатун* дигән атама кулланыла иде. Югарыда искә алынган ике гыйбарәнең берсе хатын-кызга һавалану һәм ләззәтләнү[2] күзлегеннән карашны белдерсә, икенчесе, ягъни *хатун* (خاتون) дигәне, аңа карата булган ихтирамга һәм кадерләүгә нигезләнгән[3]. Икесе дә гаять гүзәл караш була алсалар да, Шәрыкта кабул ителгән караштa изгеләштерү сизелә, олылау галәмәте бар.

*Хатун* сүзе, сан ягыннан да, хөрмәт ягыннан да, *хакан* (خاقان), *каан* (قآن) сүзләре шәкелендә ясалган сүз.

Гарәп язучылары, фарсы шагыйрьләре *хатун* сүзен күплек санында кулланганда *хаватин* (خواتين) дисәләр дә, төрек телендә *хатун* һәрвакыт шул килеш кала, һичбер вакыт үзгәрми. Ханымнарның саны никадәр ишәйсә дә, *хатун* сүзе һичбер вакыт күплек шәкеленә әйләндерелми, һәрчак шул рәвешендә кала. *Хатун* сүзенең күплеге *хатунлар*, сәййидәләрнең, аналарның әдәпләре кебек, йөзләре-куллары кебек, күзләре-башлары кебек, һәрвакыт салим[4] була, һәрвакыт сәламәт булып кала.

Төркиядә ханым-әфәнделәр *кадын* (قادين) дип атала, Русиядә төрек абыстайлары *катын*дыр (قاتن). Ләкин төрекләрдә, Төркестанда[5], гомумән – Туранда[6] өй бикәләре, гаилә аналары *хатун*дыр (خاتون).

*Хатун* сүзе мәгънәсендә ханымнарга карата олы хөрмәт, олы мәртәбә булганга күрә, падишаһларның, солтаннарның

---

[1] рафика – юлдаш; дус, иптәш (хатын-кызларга карата; ир-атка карата – рафыйкъ).

[2] ләззәтләнү – тәм табу; рәхәтләнү; кәефләнү.

[3] хатун (خاتون) сүзе гарәп теленә төрки телдән үтеп кергән.

[4] салим – сәламәт, таза.

[5] Төркестан – әлеге тарихи-географик атама даирәсенә элеккеге Советлар Берлегенең Урта Азия республикалары керә.

[6] Туран – бу тарихи-географик атама үз эченә Советлар Берлегенең Урта Азия җөмһүриятләре белән бергә Көньяк Кавказ, Анадолу (Төркия), Шәркый Төркестан (Синҗән-Уйгыр Автономияле Вилаяте) һәм төрки халыклар яши торган башка җирләрне ала.

сәййидәләрен, зәвеҗләрен[1] гарәп әдипләре *хатун* титулы белән олылый торган булганнар. *Хатун* – гарәп телендә патшаларның тормыш иптәшләренә карата кулланыла торган атамадыр. Шулай ук бу сүз хөрмәте, шәрәфе олы булган ханымнарга, сәййидәләргә карата кулланыла. Зур гаиләләрнең *кәримәләрен*, кызларын кияүгә алу мәгънәсендәге *хитáн* (ختان), *мөхáтәнә* (مخاتنة) *кәлимәләре* дә *хатун* (خاتون) сүзеннән ясалганнар.

Бер мисал: (خاتن على رسول الله صلى الله عليه وسلم)[2], ягъни, «*батыр Гали*[3] *Сәййидел-вөҗүд хәзрәтләренең матур кызы Фатыйма, галәйһас-сәлам, хәзрәтләрене хатун итеп алды, хатун итте*». Тагын бер мисал: (خاتن النبى ابا بكر و عمر)[4]. Бу җөмләдә дә «*Сәййидел-вөҗүд, галәйһис-саләтү вә-с-сәлам, хәзрәтләре Ситдыйк*[5], *Фарук*[6] *хәзрәтләренең кызларын хатун итеп алды*»,– диелә.

Зур гаиләләрдән хатын алу – гарәп телендә *хатунә*дер (ختونه). Каенана бәдәви[7] гарәпләрнең *лисанларында хатәнә*дер (ختنه).

Ягъни, төрек хатуннарына хас булган олы хөрмәт, бөек *шәрәф*, *хатун* сүзендә булган гүзәл мәгънә бәдәви гарәпләргә

[1] зәвеҗ – ир хатыны, ир кешенең тормыш иптәше; (супруга).

[2] әйтелеше: хáтәнә галиййү расүлә аллаһи, салләллаһу галәйһи вә сәлләмә.

[3] Гали (Гали ибне Әбү Талиб, 599–661) – Мөхәммәд пәйгамбәр салләллаһу галәйһи вә сәлләмнең сәхабәсе, тудыгы (туганнан туганы), кияве, сәясәт вә дәүләт эшлеклесе, Тугры хәлифәләрнең дүртенчесе (656–661).

[4] әйтелеше: хáтәнәән-нәбиййү әба бәкра вә гомәра.

[5] Әбү Бәкер әс-Ситдыйк (Әс-Ситдыйк Әбү Бәкер Габдуллаһ ибне Госман әл-Курайши, 572–634) – Мөхәммәд пәйгамбәр салләллаһу галәйһи вә сәлләмнең сәхабәсе, дусты; ислам динен дүртенче булып кабул иткән ирекле кеше; сәясәт вә дәүләт эшлеклесе, беренче Тугры хәлифә, 632–634 елларда идарә иткән. Мөхәммәд пәйгамбәр салләллаһу галәйһи вә сәлләмнең Мәккәдән Мәдинәгә һиҗрәт кыйлганда юлдашы Әбү Бәкер хәзрәтләре була.

[6] Әл-Фарук (Гомәр ибне әл-Хаттаб, 585–644) – Мөхәммәд пәйгамбәр салләллаһу галәйһи вә сәлләмнең сәхабәсе, Тугры хәлифәләрнең икенчесе (634–644).

[7] бәдәви (гарәп.; шулай ук: бәдәвият) – чүл вә сахраларда күчмә тормыш итүче гарәпләр.

дә, Җаһилият дәвере[1] бәдәвиләренә дә, Рисаләт гасырында да ачыктан-ачык мәгълүм иде.

Гаять гаҗәптер ки, хатын-кызларга карата «*гаурәт*» (عورت)[2] *кәлимәсен* куллану тел ягыннан да, әдәп-әхлак ягыннан да, зәвыклылык ягыннан да ялгыш бер күренеш. Үзегез карагыз: хатын-кызлар Төркиядә *ханымнар* дип, Иранда *зәннәр* вә *зәгыйфьләр* дип, Кырымда *кыска аяклар* дип, Төркистанда *гаҗизәләр* дип аталалар. Әмма, нидәндер һәм ничектер, фикъһы китапларында өртүле бөтен әгъзаларны белдергән *гаурәт* сүзен дә хатын-кызларга карата куллану тәмам аптыраашта калдыра. *Гаурәт* сүзен болай куллану Коръән кәрим сүзләрен тәхриф кыйлудан[3] кала берни түгел.

Мәгънәләре күп булган гаять гүзәл «*гаурәт*» сүзе Коръән кәримдә дүрт урында бар. Берсендә гаять нәзаһәтле[4] бер киная ителеп, өч урында, мәсәлән (يَقُولُونَ إِنَّ بُيُوتَنَا عَوْرَةٌ وَمَا هِيَ بِعَوْرَةٍ)[5] дигән айәт кәримәдә ул сүз тәмам башка мәгънәләрдә иңгән. (يَقُولُونَ إِنَّ بُيُوتَنَا عَوْرَةٌ وَمَا هِيَ بِعَوْرَةٍ)[6] дигән айәтнең сүзләрен башкача куллану, минем уйлавымча, әдәп кысаларыннан чыгып китә торган эш. Аерым алганда, өртүле әгъзаларга һәм хатын-кызларга карата «*гаурәт*» сүзен куллану ханым-әфәнделәрнең олы хөрмәтләренә, кадерләренә бик зур һөҗүмдер.

---

[1] Җаһилият дәвере (шулай ук: Җаһилият) – гарәпләрнең ислам дине килгәнгә кадәр дин, мәдәният, әхлак якларыннан гаять түбән дәрәҗәле булган яшәешләре.

[2] «гаурәт» (عورت) (гарәп.: عورة) – кеше гәүдәсенең ят кешеләргә күрсәтергә ярамаган өлешләре: ир-ат булсын, хатын-кыз булсын – шәригать күзлегеннән караганда, кеше гәүдәсенең гаурәт өлешләре ят карашлардан яшерелгән, ягъни өртүле булырга тиеш.

[3] тәхриф – Коръән айәтләренең мәгънәсен үз дәгъваңа туры китерү өчен андагы сүзләрнең урыннарын алмаштыру, яки аерым сүздәге хәрефләрнең урыннарын алмаштыру исәбенә шул сүзнең мәгънәсен үзгәртү.

[4] нәзаһәтле – игелекле, турылыклы, намуслы.

[5] «Алар: «безнең өйләребез саксыз [гаурәт] калды» – диделәр, тик алар саксыз [би-гаурәт] түгел иделәр» (Коръән, 33:13).

[6] «Алар: «безнең өйләребез саксыз [гаурәт] калды» – диделәр, тик алар саксыз [би-гаурәт] түгел иделәр» (Коръән, 33:13).

Өртүле әгъзаларны *гаурәт* дип атау хата булса, хатын-кызларга карата *гаурәт* сүзен куллану олы гөнаһ.

Бөек остаз Шәмсетдин Сами[1] хәзрәтләре «әмер итү» мәгънәсендә булган *кадамак* шәкеленнән *кадун* сүзен чыгарып: «*Кадун* сүзенең гарәпләшкән әйтелеше *хатун*дыр»,– дигән булса да, *хатун* сүзе чын төрки сүздер. Төрек сәййидәсе, төрек анасы *хатун*дыр. *Хатун* үзебезнең анамыздыр. *Хатун* сүзе борынгы гүзәл малыбыздыр.

(آمنه خاتون محمد آنسى * اول صدفدن طوغدى ايل دردانەسى)[2]

Бу бәет балигълык[3], садәлек[4], сафлык яклары белән төрек әдәбиятының анасы булырга лаеклы гаять гүзәл китапның беренче бәетедер. Аның югары дәрәҗәдәге аһәңлелегенә[5] тиң булган башка бер мисалның табылуы кыен.

Биредә *хатун* сүзе тышкы мәгънәсендә *ана* мәгънәсендә булса иде, бәетнең бөтен шигъри осталыгы, *кадын* сүзе кебек, иран зәгыйфәсе кебек, *гаурәт* мәгънәсенә кайтып калыр иде.

Әмер итү мәгънәсендә *кадамак*[6] (قادامق) сүзе Шәмсетдин Сами хәзрәтләренең бөек хәтерләрендә яки хыялларында бәлки бардыр да. *Кадамак* кебек бер сүздән *кадун* (قادون) кебек сүз чыгару һөнәре ялгыз Шәмсетдин Сами, разый Аллаһу ганһу, хәзрәтләре кебек сүз ясалышы даһиләренең кулыннан килә торган эш. *Кадамак* сүзеннән *кадун* сүзен ясау, фараз итик[7], раслана алса иде, *хатун* (خاتون) сүзе, төрекчәдәге *хатун*, төрекчәдәге *ана* кебек, тәмам мөстәкыйль, тәмам чын төрки сүз булыр иде. *Кадамак* сүзеннән *кадун* сүзенең килеп

---

[1] Шәмсетдин Сами (1850–1904) – госманлы дәвере сәхнә әсәрләре язучы; драматург.

[2] укылышы: Аминә хатун Мөхәммәд анасы, Ул сәдәфдән тугды ил дәрданәсе; тәрҗемәсе: Әминә хатун – Мөхәммәднең әнкәсе, Шул сәдәфтән туды ил җәүһәре.

[3] балигъылык (гарәп.) – җитешкәнлек, җиткән булу; биредә: үтемлелек, әдәби осталык.

[4] садә – гади; катлаулы булмаган.

[5] аһәң – көй; көйлелек; гүзәл аваз.

[6] ягъни кадарга; «әмер итү» мәгънәсендә бу сүз када булып килә, шуннан кадын сүзе ясала, имеш.

[7] фараз итик – күз алдыбызга китерик.

чыгышы дәлилле булса иде, Рума кануннары[1] кебек үк булмасалар да, *кадун* сүзе Төркия хакимнәренең гүзәл бер атамасы ителгән булыр иде. Һич югында, Төркиядә *кадун* сүзе *хакимнәр* билгесе буларак, әлбәттә, кулланылыр иде.

Төрек гаиләләрендә хатын-кызларның үзләре кебек, ханымнарның бүлмәләре дә, торган урыннары да *гыйсмәт* коймасы белән әйләндереп алынып, хөрмәт сакчылары белән сакланыр иде. Шуңа күрә, хатын-кызларның бүлмәләре дә, Кәгъбә хәрәме[2] кебек, Рауза хәрәме[3] кебек, хәрәм[4] булыр иде.

(حرم: محفوظ حصن اهتمام است * حرام است زياده يك الف در وى)[5]

Төрек суфый Аллаһияр[6] хәзрәтләре «*Морад әл-гарифин*»дә[7] бу гүзәл бәетне төрек хәрәмнәренең хакыйкый әһәмиятләрен үтемлелек кысаларыннан ашкан тугры рәвештә бәян иткән. Хәрәм, әлбәттә, саклана торган урын, хәрәм

[1] Рума кануннары – Рим хокук системасы.

[2] Кәгъбә хәрәме – Кәгъбәнең үзе, ягъни аның бинасы күздә тотыла.

[3] Рауза хәрәме – Мөхәммәд пәйгамбәр салләллаһу галәйһи вә сәлләмнең Мәдинәдәге йорты.

[4] хәрәм – изге урын, тыюлык (хәрам сүзе белән бутамаска); Мәккәдә урнашкан изге Кәгъбә һәм аның әйләнәсендә гыйбадәт кылу өчен төзелгән корылмалар комплексы әл-Мәсҗид әл-Хәрәм, ягъни «Изге (Ясак) мәчет», дип атала; моннан тыш хәрәм мөселман йортының хатын-кызлар өчен махсус аулак кылынган бүлмәсе яки өлеше – хатыннар ягы; әлеге сүз урыс теленә ике шәкелдә: храм һәм гарем буларак үтеп кергән.

[5] Фарсычадан тәрж.: «Хәрәм (حرم) ул кайгыртылуның һәм кадерләп багылуның изге тыюлыгы / Аңа Әлиф хәрефен кушсаң, ул Кәгъбә харамена (حرام) әйләнәчәк.

[6] суфый Аллаһияр (1616–1713) – әсәрләрен төрки телдә язган Төркестанлы суфый шагыйрь.

[7] «Морад әл-гарифин» («Белүчеләрнең максатлары») – суфый Аллаһиярның рухияткә багышланган шигъри әсәре. 1858 елда Мәскәүдә типографик ысул белән басылып чыккан. Халык арасында әсәрнең кульязма күчермәләре киң таралган булган.

ул – ихтирам кальгасыдыр[1]. Бер әлифне кушсаң, төрек хәрәме Кәгъбәтү-л-Лаһ[2] кебек әл-Бәйт әл-Хәрам[3] булачак.

Төркия сарайларының, төрек пашаларының[4] (Harem) нәре ил белән идарә иткән солтаннарның күңел ачулары өчен, аралашулары өчен махсус рәвештә аулак кыйлынган одалардан[5] гыйбарәт исә дә, гади төрек гаиләләренең хәрәмнәре, төрек ханымнарының, аналарының, кызларының хәрәмнәре аларга караган махсус хөрмәт вә ихтирам күрсәткечдер. Ислам сәййидәләренең, төрек хатын-кызларының хиҗаблары да хөрмәт *ихрамыдыр*, *шәрәф* билгеседер, сафлык зиннәтедер.

Коръән кәрим айәт кәримәләрендә берничә мәртәбә искә алынган хиҗаб – рухи хиҗаб булса да, күз белән күрелә торган хиҗаб булса да, һәр икесе безгә мәгълүм булган мәгънәдә, Шәрыкта билгеле булган шәкелдәге матди хиҗаб түгел. Бу китабымның махсус бер бүлегендә хиҗаб мәсьәләсе тикшерелер, иншаллаһ.

## Бер бөек ислам шагыйренең хатын-кызлар хакында гакыйдәсе

Москва хөкүмәте белән Русия мөселманнары хозурында[6] хөрмәтле олы кунак буларак, инкыйлабтан соң Русиядә еллар дәвамында яшәп, Америкада вафат булган мәүлави[7] Бәрәкәтулла Сахиб хәзрәтләре урду, инглиз, фарсы, гарәп әдәбиятлары белән бик тә якыннан таныш булган бөек бер шагыйрь иде. Һиндыстанның бөек остазларында бергәләп сабак алган булуыбыз аркасында мин дә аның дусты булу шәрәфенә ия идем. Ленинградта берничә мәртәбә минем өйемдә кунак

[1] кальга – кирмән; ныгытма.

[2] Кәгъбәтү-л-Лаһ (гарәп.) – Аллаһ Кәгъбәсе.

[3] әл-Бәйт әл-Хәрам (гарәп.) – Хәрам кыйлынган Йорт (Кәгъбә һәм аның әйләнәсендәге гыйбадәтханәләр күздә тотыла).

[4] паша – фарсы сүзе падишаһның кыскартылган шәкеле; Госманлы илендә, Мисырда хәтта 1952 елга кадәр югары дәрәҗәле дәүләт хезмәткәрләренә карата кулланылган титул.

[5] ода – ханәдәге, өйдәге бүлмә; татар телендә утар шәкелендә сакланган.

[6] хозурында – күз алдында, алдында; янында, каршысында.

[7] мәүлави – дин галименә ихтирам белән мөрәҗәгать итү сүзе.

булды. Москвада айларча бергәләп яши идек. 1919–20 нче елларда Русия вилаятләрендә берничә ай бергәләп сәяхәт иттек. Мин он, тоз кебек кирәкле нәрсәләр эзләдем, Мәүлави Сахиб хөкүмәт хәйләсе белән Москвадан чыгарылган иде. Ул көннәрдә Әфган хөкүмәте тарафыннан бер сәяси оешма Москва хөкүмәте хозурына килгән иде.

Мәүлави Бәрәкәтулла Сахиб җәнабләренең гарәп телендә каләме дә, иншасы[1] да бәлягатьле[2] иде, дөрес була иде, җиңел яза иде. Яхшы язучы иде. Фарсы теле исә бик тә дөрес иде, гаять иркен иде. Мәүлави Җами[3] хәзрәтләренә иярерлек кадәр гүзәл шигырьләр яза иде. Берничә шундый язмаларын миңа бүләк итте. «Гаһед гатыйк», «Гаһед җәдид»[4] китапларын да яхшы белә иде. Коръән кәримнең кыска сүрәләренә фарсы телендә язган гаять гүзәл тәфсирендә «Гаһед гатыйк», «Гаһед җәдид» китапларының җөмләләрен хөҗҗәт[5] рәвешендә җай чыккан саен китерә. Ул тәфсирен Төркестан, Әфганстан яшьләренә Коръән кәримне укыту өмете белән язган булган. Әфган ханы Хәбибулла Хан хозурында кунак исеме белән өч елга сузылган хурлыклы мәхбүслек[6] вакытында Мәүлави Бәрәкәтулла үзенең тәфсирен Фәхретдин Рази[7]

---

[1] инша – биредә: әдәби иҗат; язу иҗаты.

[2] бәлягать – сөйләм һәм язма телнең матурлыгы, төзеклелеге, бәян ителәсе фикерне җиткерүдә камиллеге.

[3] Мәүлави Җами (Нуретдин Габдеррахман ибне Әхмәд Җами; 1414–1492) – данлыклы фарсы суфый шагыйре, тәсаувыф (суфыйчылык) остазы, илаһият белгече, фәлсәфәче, музыка белеме остасы.

[4] «Гаһед гатыйк», «Гаһед җәдид» – «Тәүрат» белән «Инҗил»ләр, ягъни «Ветхий Завет» һәм «Новый Завет».

[5] хөҗҗәт – рәсми кәгазь; ышанычлы чыганак, дәлил; (документ).

[6] мәхбүслек – тоткынлык; зинданга ябылган булу.

[7] Фәхретдин Рази (Фәхретдин Әбу Габдулла Мөхәммәд ибне Гомәр әр-Рази, 1149–1209) – әшгари агымындагы кәламнең күренекле вәкиле, исламны яңартучы (мөҗәддид) имамнарның алтынчысы буларак танылган. Аның каләме белән «Тәфсир кәбир» («Олуг тәфсир») исемле Коръән тәфсире һәм «Мәфатихе-л-гайб» («Яшереннең ачкычлары») исемле тәмамланмаган Коръән тәфсире язылган.

хәзрәтләренең төрбәсе янәшәсендә аның «Тәфсир кәбир»ен тулысынча укып чыгу бәрәкәте белән хасил булган зур тәэсирнең этәрүе белән язган имеш. Бервакыт миңа боларны бер хикәя сөйләгән кебек сөйләде. Хәбибулла Хан хозурында да, Москва хөкүмәте хозурында да сәяси өметләрен тормышка ашыра алмыйча, Москвадан китеп барганда, тәфсирен миндә калдырды. «Аны бастырып, тарата алсагыз, Төркистан, Әфганстан таләбәләре өчен, шәт, файдалы булыр!»,– диде. Соңрак, бервакыт миңа Берлиннан хат язуб: «Тәфсиремне мөхтәрәм Габделкадир әфәнде Мөхитдин[1] җәнабләренә бир; ул бастырыр»,– диде дә, мин тәфсирне тапшырдым. Гаять гүзәл вә әһәмиятле тәфсирдән китапханәм мәхрүм калды. Ихтимал, югалмас. Төркестан мөселманнары ул гүзәл тәфсирне бервакыт, ихтимал, нәшер итәрләр. Бары тик минем хәтеремдә сакланган бу әманәтне биредә җай чыкканнан гына яздым.

Мәүлави Бәрәкәтулла хәзрәтләре Коръән кәримне бик яхшы белә иде. Хәдис китапларының да барысын укыган, игътибар белән өйрәнеп-тикшереп чыккан бер адәм иде. Ә инде мәзһәб китабларына килгәндә, алар белән кызыксынмый иде. Иҗтиһадчы булуын дәгъваламаса да, мәзһәбләрнең һичберенә тәкълид итми[2] иде. Әһәмиятле мәсьәләләрдә мөстәкыйль хөр фикерләре дә бар иде.

1908 нче елда Төркиядә инкыйлап булып узганнан соң, Төркия хәлләрен, үзенең күптәнге хөррият[3] рафыйкъларын күрү нияте белән Токиодан Истанбулга барышлый, 1911 нче

---

[1] Габделкадир әфәнде Мөхитдин (1992–1934) – яшь Бохаралылар хәрәкәте вәкиле, җәдидче; Бохара Халык Совет Руспубликасын төзүчеләрнең берсе; соңрак дәвердә Таҗик ССРның Халык комиссарлары Шурасы рәисе булган, кулга алынган вакытында Үзбәкстан Совет Социалистик Республикасының тәэмин итү халык комиссары булып хезмәт иткән.

[2] тәкълид итү – киң мәгънәдә: кабатлау; махсус мәгънәдә: шәригать хөкемнәрен булдыру эшендә борынгы фәкыйһләрнең карарларына, хөкемнәренә, фәтваларына иярү.

[3] хөррият – азатлык; ирек.

елда Ленинградны зиярәт итте[1], бер атна кадәр миндә кунак булды. Һәммә музейларны, төрле оешмаларны бергәләп тамаша итдек. Урынлы булган саен дини, сәяси, әхлакый мәсьәләләр турында үзенең фикерләрен һәрвакыт иркле бер тел белән бәян итәр иде. <…>

Бервакыт Москвада бөек салоннарның берсендә мәвләви Бәрәкәтулла хәзрәтләре белән бергә идек. Анда берничә кеше бар иде. Арада ике-өч ханым әфәнделәр дә бар иделәр. Утырырга мөмкинлек юк иде, тик җәмәгать аягурә булса да, мөхтәрәм кунакның, бөек сәяхәтченең сүзен ишетергә теләк белдерде. Аңлаттым. Бәрәкәтулла хәзрәтләре кыска гына итеп берничә гүзәл җөмлә әйтте. Ничектер, бер мөнәсәбәт белән Япония һәм Америка ханымнарын да бераз искә алды. Шул вакытта әйтелгән сүзләренең берничә җөмләсе минем хәтеремдә калды:

«Бөтен кяъинәтне[2] халык иткәннән[3] соң, Нәкъкаш-е әзәл[4] Ләүхе галәмдә[5] кодрәт каләме белән адәмне рәсем итте дә, ахырда, тагын да бөек, тагын да кямил бер осталык белән җиһан тактасында хатын-кыз йөзен, хатын-кыз гәүдәсен нәкыш итте. Хатын-кыз Нәкъкаш-е әзәлнең иң соңгы сәнгате булды. Мондый гүзәл бер сурәткә Иблис сәҗдә итмәве белән үзенең җаһиллеген фаш итте вә буйсынмаучы булды. Ир-атның йөрәге бер тәхеттер, бары тик әдәпле, саф ханым ул тәхетнең мәликәсе[6] булыр»,– диде.

---

[1] зиярәт итү – күрешергә бару; хәл белергә бару; күрү нияте белән, шунда булып алу нияте белән кая да булса бару.

[2] кяъинәт – космос.

[3] халык итү – барлыкка китерү; булдыру.

[4] Нәкъкаш-е әзәл – Мәңгелекне Бизәүче (Аллаһ).

[5] Ләүх-е галәм (Галәм тактасы) – ягъни галәм язу тактасы белән чыгыштырыла; ләүх (гарәп.) «такта», татар теленә ләүкә рәвешендә кулланыла.

[6] мәликә – падишаһ/патша ханым.

Мин бөек шагыйрьләрнең сүзен яратып кабул итәм. Бу йөздән Төркия шагыйре «Мөхәммәдия»не[1] язган Язызы Задә[2] хәзрәтләренең бәетләре исемә төште:

*Җиһан ләүхендә кешене шундый итеп ясады ки Нәкъкаш,*

*Фәрештәләр күрделәр дә аны, диделәр: «Аның ятраткана әфарин!»*

*Әмма иблис сәҗдә итмәде, белеп тор кемнең һичнәрсә белмәгәнен:*

*Ни тышын белде, ни эчен, ни нәкышне белде, ни Нәкъкашне.*

Бөек шагыйрьнең мондый сүзләрен мин, әлбәттә, яхшы дип табам. Мондый сүзләр, мөгаен, бөек әдәпнең, гаять нәфис, саф хиссиятнең чагылышы була ала. Хайванлык куәте кешеләрне иң түбән, иң вәхши хәлләргә төртеп төшерә алса да, матурлыкның һәрнәрсәне җиңә торган куәте кешеләрне иң югары кямиллекләренә ирешергә чакыра, иң бөек омтылышларга таба тарта.

Дөрес, мин дә беләм, хатын-кызларга хас гүзәллек, матурлык гаять зур илаһи бүләк булса да, матурлыкның һәрнәрсәне җиңә торган куәтенең әхлакый хәяттә, иҗтимагый хәяттә әһәмияте гаять зур булса да, матурлык хатын-кызларда мәхәббәтнең һәрнәрсәне җиңә торган куәтенең бер чагылышы була алса да, ул куәт, ни дисәң дә, олы хөрмәтнең нигезе була алмый, яки аның нигезе ителә алмый.

Хатын-кызлар җәмгыятьнең бары тик бер зиннәте түгел, алар милли кәмиллекнең дә зур байлыгыдыр. Хатын-кыз

---

[1] «Мөхәммәдия» – Мөхәммәт пәйгамбәргә (ﷺ) багышланган тарихи, әдәби-әхлакый, нәсихәтчел шигъри әсәр; XX гасыр башларына кадәр, татарлар арасында киң таралыш табып, яратып укылган китапларның берсе.

[2] Язызы Задә (Мөхәммәд Чәләби Язызы Задэ; милади 1451-дә вафат) – госманлы дәүләтенең күренекле дин галиме, суфый, гарәп һәм фарсы телләре белгече, мөфәссир, мөхәддис (хәдис белгече), мөтәкаллим, фәкыйһ.

хөрүм михрабларының[1] бер сынымы[2] түгел, ул өммәтнең дә бөек бер вәлидәседер.

Мәхәббәт бер нигез булса, хөрмәт аннан да олырак нигездер.

Һәр өммәт матурлык бәндәседер. Матурлык каршында иблис бер гасый[3] булса да, фәрештә һәрвакыт сәҗдә итәр. Дөрес, шулайдыр. Ләкин хикмәт бары тик моның белән канәгатьләнми. Мәхәббәт, сөю көчләре янында ул хөрмәт, ихтирам нигезләренең булуын да таләп итә.

Иҗтимагый тормышта хатын-кызларның әһәмиятләре хакында Гаребнең карашы белән Шәрыкның карашын да сурәтләдем. Гаребнең карашы күбрәк нәфсани ләззәт[4] якларына бераз авышучан булсада, Шәрыкның карашы рухани ихтирам үзәгендә нык тора. Коръән кәрим тәгълимнәрен тиешенчә үзләштергән бөек бер шагыйрьнең ихлас саф карашын да биредә матур бер хатирә буларак, урынлы булганга күрә хикәя иттем.

Америкада күмелгән хөррият шәһите, үзенчәлекле, бөек ислам шагыйре, хикмәт иясе мәүлави Бәрәкәтулла Сахиб хәзрәтләренең матур хатирәләрен әдәп мәҗлесләрендә тергезеп, фикерләрен бу сәхифәләрдә тәкъдим иттем. Мәрхүмнең рухларына бер дога итү, дога иттерү; үзенә бер ихтирам күрсәтү, ихтирам күрсәттерү нияте белән эшләнгән эш иде.

Инглиз[5] сәясәте аркасында ватаннарыннан сөрелгән мәүлави Бәрәкәтулла, мәүлави Габидулла, Әбу Сәгыйд әл-Гарәби, мәүлави Габдерраб, мәүлави Габделҗәббар, мәүлави Габдессаттар, Раджә Пәртап кебек, Шәрыкның бөек шәхесләре, Җиһан сугышыннан соң һичбер җирдә үзләренә урын таба алмыйча, Гареб илләрендә шәһәрдән шәһәргә сө-

[1] хөрүм михраблары – йортларның, сарайларның махсус сурәттә хатын-кызлар өчен төзелгән яки башкалардан аулак ителгән өлешләренең, бүлмәләрнең мәчетләрдәге михраб дәрәҗәсендә изге урын булулары күздә тотыла.

[2] сыным – нәрсәдән дә булса ясалган сын, скульптура.

[3] гасый – буйсынмаучы, баш күтәрүче, гыйсьянчы.

[4] нәфсани ләззәт – тән рәхәте.

[5] Инглиз – Англия.

релеп, суыгылып йөрерләр иде. Һичбер җирдә, хәтта Төркия, Иран, Әфганстан кебек ислам илләрендә якты чырай әсәрен күрмичә, этелгән-төртелгән хәлдә гомер кичерерләр иде. Бары тик Москва хөкүмәте хозурында олы кунакчыллык күреп, хөрмәттә, рәхәттә еллар дәвамында кунак булып тордылар.

Ул бөек шәхесләрнең һәрберен зиярәт итеп тордым, һәрбере мине зиярәт итә иде. Ханәмдә[1] кунак булырлар иде. Мәгълүматләреннән, әдәпләреннән, фикерләреннән файдалана идем.

---

[1] ханәмдә (фарс.: ханә) – өемдә.

## Финляндиягә язган хатларыннан[1]

…5 март[2] тарихлы мәктүбегезне алдым. Багдадта алып укыдым. Сәяхәткә чыгачагым көннәрдә иде Шамнан мәктүп язармын өмете белән җавабымны бераз кичектердем. Виза алдым. Хәрәкәт итеп шам капкаларына кадәр бардым. Сүрия хөкүмәте мине кире какты. Багдадка кайтып янә 4–5 көн кадәр калдым. Филистыйн юлы белән хәрәкәт итү өчен Инглиз консулына мөрәҗәгать иттем. Миңа башта хәтта кабул итмәде, соңыннан да гарантия буларак миннән 60 алтын эстәде. Бирә алмадым, шул сәбәпле виза да ала алмадым. Нусайбин станциясенә ирешкәннән соң Сүрия хөкүмәте мине кабат кире какты. Бу юлы Мосул шәһәренә кайттым. Мосуллы адвокатларның ярдәмнәре белән корылган бер план буенча аларның сүзләренә, күрсәтмәләренә һәм килешүләренә инанып, Захо юлы белән, Төркия җирләренә кичү максаты белән Захо шәһәренә хәрәкәт иттем. Бу шәһәрдән атка атланып Төркиягә кичәсе идем. Захода гарәп сәййидләренең беренең өендә кундым. Атлар белән мине озата барулары өчен Мосулдан үзләренә әмер бирелгән иде. Сезне ат белән юлга чыгарганчы тагын да ышанычлы бер юлга чыгарыйм диде. Инандым. Минем бөтен әйберләремне үзенең салына төятте. Үзе дә минем белән бергә 4 кешесе белән, барыбыз бергә салга менеп утырдык. Хабур исемле шәһәрдән елганың агымына ияреп киттек. Минем өчен бу, башлангычы яхшы бер тамаша иде. 4 сәгать хәрәкәттән соң туктадылар. Салны бәйләп

---

[1] Чыганак: Uralgiray, Yusuf. Üstâdimiz Musa Cârullah'ın «Finlandiya Cemaat İslâmiyesi» başkanı hafiz imam Veli Ahmed Hakîm hazretlerine muhtelif tarihlerde yazdığı mektuplar. Filozof Musa Carullah Bigi. Uzun Günlerde Oruç. İctihad Kitabı / Eseri sadeleştirerek dipnotlarla işleyen Yusuf Uralgiray. Ankara, 1975. / Uralgiray, s. 15–17. (Татар теленә тәрҗемә ителде).

[2] 1934 елның март ае.

куйдылар. Төркия җирләренә иң якын нокта нәкъ менә бу урындыр, диделәр дә мине төшереп калдырдылар. Минем белән бергә салдан тагын бер кеше төште. Соңыннан яныммнан аерылып китте. [Тирә як] бум-буш чүл иде, япа-ялгыз үз башыма калдым. Өч-дүрт сәгать кадәр көттем. Иң ахырда ерактан бер кеше күренде һәм яныма килде. Йөзенә бактым, бераз шөбһәләндем. Миңа әллә нәрсәләр сөйләде, мәгънәсен аңлый алмадым. Сүзләрендә янау ишарәләре бар иде. Әйберләремә күрсәтеп: «Качак! Качак!» сүзләрен кабатлады. Инде сүзләренең мәгънәсен аңлаган идем. Янымнан аерылып китте. Фәкать мин аптыраган бер хәлдә калдым. Калебемне шикле уйлар басып алды һәм куркыныч борчылуга биреллдем. Шул ук кеше 2–3 сәгать үткәч кире килеп янә яныма килде. Бу юлы янында бер бала да бар иде. Телне белә иде. Аңладым ки, [бу] кеше авылның мохтары[1], имеш. Мин төшеп калган җиргә качкыннар килеп төшәсе, имеш. Соң дәрәҗәдә җаным кысылды. Әйберләрне алар илтеп кую өчен йөк ташучыларга 2 алтын эстәделәр. Баткаклык җирдә 3–4 километр бер араны бата-чыга үттек. Мохтарның өендә кунып калдым. Хәсрәт эчендә изелеп куырылдым. Иртә уяндым. Таможня тикшерүе өчен конвойчы кулында 3–4 сәгать кадәр вакыт бардык. Әйберләремне тикшерделәр. Сандыкларымда китапларымнан башка бер нәрсә юк иде. Протокол төзеделәр. Бу юлы 2 жандарма офицеры кулында полиция үзәгенә китерелдем. Көчле бер тел белән башкарылган сораштырмадан соң бик кырыс вә гаять дикъкатьле сурәттә бөтен әйберләремне зәррәсенә кадәр актарып тикшереп чыктылар. Озын бер протокол төзелде. Өч көннән соң ике конвойчы кулында Җизрә шәһәренә җибәрелдем. Бер төн караколда[2] үткәрдем. Иртән иртүк бер жандарма офицеры белән шәһәрнең каймакамы[3] хозурына китерелдем. Миңа рөхсәт бирелде. Җизрә шәһәрендә, кунакханәләрендә 4 көн үткәрдем. Бу шәһәр тарихта мәшһүрдер. Фәкать бүген авыл кебек бер харәбәдер. Каршыма бер йөк

[1] мохтар – халык тарафыннан сайланып куелган староста.

[2] каракол – полиция участогы.

[3] каймакам – шәһәр башлыгы; администрация җитәкчесе.

машинасы, бер автомобиль килеп туктады. 20 лира түләп 200 километр ерактагы Мардин вилаятенә җибәрелдем. Юлда 4 көн газап чиктем. 16 апрельдә Мардин шәһәренә ирештем. Караколда бер төн үткәрдем. Иртән мине полиция мәркәзенә китерделәр. Мәркәз ишек алдында көттем. Бер офицер килде. Вәли хәзрәтләре сезне дәгъвәт итә, диде. Хозурына бардым. Мине зур илтифат вә ихтирам белән каршылады. Хәлемне сорады. Ачыкладым. Миңа чәй тәкъдим итте. 4–5 темага кагылып узды. Бер сәгать кадәр сөйләшеп утырдык. 4–5 кеше килде. Мине аларга танытты. Сезне бик яхшы беләм, диде. Соңыннан әхвәлемне сорады. Ачыкладым. Кулымда акча юк, фәкать чекларым бар, дидем. Боздырыйк[1], диде. Телефон аша банк мөдиренә әмер бирде. Инде акча итеп ала алмасагыз һәм акча таба алмасагыз, миңа хәбәр бирегез, диде һәм ихтирам белән мине озатып җибәрде. Үзләренә тәшәккерләр әйттем һәм шатланып аннан чыктым. Бөтен мөгамәләләремне башкарып чыкканнар иде.

Мардин Паласта 30 сәгать кадәр үткәрдем. Икенче көн Мардиннан Аданага кадәр билет алдым. Башка акчам калмаган иде, әмма мин дә котылдым. Багдадтан Истанбулга кадәр өч көнлек юлны олы газаплар эчендә 25 көн буе уздым. 70 лира кадәр тоткан 12 инглиз лирасын юкка сарыф иттем. Сезгә шушыдыр кыскача бер хикәя.

Мәктүбемдә сезгә Захо-Мардин-Истанбул сәфәрен бераз яздым, зур хурлык күрдем. Чамасыз масраф зарурәте, гаять авыр бер газап булды. Заходан башлап Искендерунга кадәр хурлыкларның ачылары калебемдә бүгенгә кадәр дәвам итте. Юклык куркуларына, тарлык кайгыларына өстәп полиция кулындагы хурлыклар, онытылган кичергән хәсрәтләрне яңадан уяндырды. 10 май көннәренә кадәр калебем, зур хәсрәтләнүләр эчендә иде. Ишемнең, кызларымның, угылларымның вә гаиләмнең хәсрәте дә эчемдә дөрләп янды. Еглау мөмкин булса иде, күз яшьләремне бераз агызып калебемне бушатыр идем.

[1] боздырыйк – акчага алаштырыйк.

Ачы хәсрәт эчендә калеб буылса, буылып калса, хурлык дакыйкаларында, тарлык сәгатьләрендә адәм баласының хәяттән тәмамән гайрәте чигә икән.13–14 май тарихларына кадәр мондый бер хәл эчендә буылып йөрдем. Бүген 15 майдыр, күңелем бераз ачылды.

Ят илләрдә горбәт хәяте олы бер газаптыр. Хәлегезгә шөкер кыйлыгыз. Минем бәдбәхетлегемне күреп һәр хәлегезгә шөкер итсәгез урынлыдыр. Үзем әүвәлге кебек сөнни исәм дә, хәятем тулысынча игътизальдер[1]. (أحد لا أرى أحداً ولايرانى)[2]. Фәкыйрьлек сәяхәтләремдә бик зур хурлыклар чиктем. Игътизалем дә шуңа күрә булды. Кулымда бераз акча булса иде, янә 4–5 китабымны гарәпчә буларак ислам милләтләренә тәкъдим итәр идем. Соңыннан вәлидәмнең[3] хозурына юнәлер идем. Бүген янә шәкерт хәленә кайттым. Дөньяда тәмамән ялгызлык хәлендәмен, ялгыз калдым. Ут, су күрер алдыннан бераз ялкынланып, яктырып китә. Вөҗүдемдәге[4] бүгенге куәт, калебемдәге фәгалият[5], мөгаен, бу төрдәндер.

---

[1] игътизаль – халык арасыннан, җәмәгатьтән аерылу. Муса әфәнде, сөнни мөселман җәмәгатьчелегеннән аерылып чыгып, үз юллары белән киткән (игътизаль сүзе белән тамырдаш булган) мөгътәзилә фиркасын күздә тота.

[2] Берәүне дә күрмим, мине дә һичкем күрми.

[3] вәлидәм – әнием.

[4] вөҗүд – гәүдә, тән.

[5] фәгалият – эш дәрте, эшлеклелек.

# Коръән кәрим[1] тәрҗемәсе[2]

Табигатьнең, бәлки дә бөтен галәме вөҗүднең тәрҗемәсе булган Коръән кәримне үз телебезгә дөрес һәм гүзәл ысул белән тәрҗемә итү, әлбәттә, тиеш иде.

Бүгенгә кадәр тәрҗемә итмәү гөнаһ булмаса да, моннан соң тәрҗемә итү һичбер сурәттә гөнаһ була алмый.

Коръән кәрим бөтен галәме вөҗүднең тәрҗемәседер, дидем.

Мин бу сүзне артырып, күпертеп, яки коры бер иман тәэсире белән әйтмәдем. Минем чын игътикадым шулдыр. Бу сүземне биредә тәфсир итмәк ниятендә түгелмен, бәлки аны исбат итәрлек хәлдә дә түгелмен. Ләкин, тәрҗемәсенә кыюлыгым җиткән Коръән кәримгә карашымны күрсәтү өмете белән бу сүзне биредә яздым.

Коръән кәрим Рабб хәкимнән[3] Җәбраил Әмин аркылы нәби кәрим, галәйһи-с-саләт вә-с-сәламнең, калебенә иңгән иң соңгы сәмави[4] китаптыр. Аның могъҗизави эчтәлегенең телләрдә, күңелләрдә, мосхәфләрдә үзгәртүсез мәңге саклануы вазифасы белән, мәгънәләрен бөтен кешеләргә бәян итмәк гаһеде белән[5], нәби кәрим, галәйһи-с-саләт вә-с-сәлам, тара-

[1] Сүз уңаеннан нигә «Коръән-и кәрим», дип түгел, «Коръән кәрим», дип язуым турында аңлатма бирүемне кирәк дип таптым. Бу турыда тулырак мәгълүмат өчен кара: Айдар Хәйретдин. «Кәламе шәриф»ме, әллә «Кәлам шәриф»ме? // Безнең мирас. № 5. 2018. С. 15–17.

[2] Чыганак: Бигиев, Муса әфәнде. Халык назарына берничә мәсьәлә. Казан: Электро-Типография «Умид», 1912. Б. 85–93. (Өзек, татар теленә тәрҗемә ителеп, кыскартылып бирелә).

[3] хәким – хикмәт иясе.

[4] сәмави – күктән, Аллаһтан иңдерелгән.

[5] гаһеде белән – биредә: шарты белән.

фыннан илаһи әманәт буларак Коръән кәрим мәгъсум[1] өммәт исламия җаваплылыгына тапшырылды.

Могъҗизави эчтәлекнең мәңге бакый калачагы Шаригъ хәкимнең[2] бөек тәдбире бәрәкәтендә тәэмин кыйлынмыштыр.

Иңгән һәрбер айәт кәримәне саклап калу мөэминнәрнең һәрберенә Гаср-е сәгадәттә иң беренче фарыз иде. Коръән кәрим Гаср-е сәгадәттә зур теләк белән сакланылды, һәр хәрефе, һәр айәт кәримәсе тәмамы белән язылды.

Сәмави китапларның һичберенә насыйп булмаган шәрәф,– расүл исән чакта тәдвин шәрәфе[3],– Коръән кәримнең насыйбы булды. Ике хәлифә гасырында һәммә әсхаб кирамның[4] иҗмагы белән[5] тугыз мосхәф язылды. Ул мөкаддәс мосхәфләрдән нөсхә кыйлынып хисабы юк мәсахиф язылып, әүвәлге гасырда мәчетләрнең һәрбере, ханәләрнең күбесе мөкаддәс мосхәфләр белән бизәлде.

Ул вакытта Коръән кәримнең хамилләре[6], хафизлары өммәтнең иң бөек катламы, иң хөрмәтле әфәнделәре кебек игътибар кыйлына иде. Шуңа күрә, Коръән кәримне саклауны һәр нәрсәдән ныграк теләделәр. Коръән кәримнең хәрефләре, кәлимәләре, вөҗүһләре[7], нөктәләре[8] гаять бөек дикъкать белән теркәлде.

Тилавәт[9] – исламиятнең рөкене булды. Һәр көннең биш намазы рәкәгатьләрендә Коръән кәрим айәт кәримәләрен гарәби назым белән уку[10] намаз рөкеннәренең иң бөеге кыйлынды. Гарәби назым белән Коръән кәрим айәт кәримәләрен

[1] мәгъсум – гөнаһсыз, гаепсез, пакь.

[2] Шаригъ хәким – шәригатьне булдыручы хикмәт иясе, Мөхәммәт пәйгамбәр.

[3] тәдвин шәрәфе – язуда теркәлеп калу мәртәбәсе.

[4] әсхаб кирам – Пәйгамбәрнең сәхабәләре.

[5] иҗмагы белән – үзара килешүләре белән, уртак карары белән.

[6] хамил – биредә: Коръән нөсхәсе иясе.

[7] вөҗүһ – биредә: Коръәннең рәвеше, шәкеле.

[8] нөктә – нечкәлек, үзенчәлек.

[9] тилавәт – Коръәнне ишетелерлек итеп көйләп уку.

[10] гарәби назым белән уку – гарәп телендә ничек ишетелгән булса, шулай уку.

тилавәт – әһле исламның иң бөек зикерләре[1], иң мөкаддәс гыйбадәтләре, иң ләззәтле гамәлләре булды.

Шаригъ хәкимнең шул бөек гадәте Коръән кәримне мәңгегә саклау хакында иң мәгъкуль, иң файдалы гадәттер.

Тилавәт тик гарәби назым белән була.

Намаз рөкеннәрендә, зикерләрендә, савап казану максаты белән укуда, дәлилләр китерү хосусларында тик гарәби назым мөгътәбәр була ала. Фарыз намазларның рөкеннәре айәтләрнең тәрҗемәләре белән әда кыйлына алмый. Зикер тик гарәби назым белән була.

Шаригъ хәкимнең шул гаять бөек гадәте уңында минем акылым, калебем сәҗдә итәләр. Могъҗиз назымның хәрефләрен, кәлимәләрен, вөҗүһләрен, шул кадәр бөек дикъкать белән теркәп калдырган имамнарның, Коръән кәрим имамнарының миллионнан бер сәналәрен[2] сөйләмәктән телем гаҗиз кала.

Мәгъсум ислам өммәте гоһдәсендә ике вазифа йөкләнгән иде дидек.

Шул ике вазифадан иң мөһиме – назым кәримне хифыз вазифасы[3] – Шаригъ хәкимнең үз тәдбире белән[4] башкарылды.

---

[1] зикер – искә алу, истә тоту. Биредә Аллаһны искә алу, Кыямәт вә Ахирәтләрне, адәм баласына йөкләнгән җаваплылыкны истә тоту күздә тотыла. Истә тоту дигәндә дә, моны хәтерләү, хәтердә саклау, дип кенә аңлау аз. Төрки телдә ис сүзе (аның мәгънәдәше булган кот сүзе дә бар) фарсы теленнән кергән җан, һәм гарәп теленнән кергән рух, сүзләренә туры килә. Бу сүзнең әлеге мәгънәсе «исем китте» («котым очты») гыйбарәсендә сакланып калган. Болай булганда зикер итү дигәндә изге нәрсәләрне хәтердә генә түгел, күңел түрендә саклау буларак аңларга кирәк. Соңгы вакытларда дөнья күргән дини китапларда зикер урынына зекер дип язу һәм уку гадәткә кергән. Болай итү тупас хатадыр, чөнки асыл сүзнең гарәпчә яңгырашы зикр. Ә инде аны зекер дип укыганда, ул гарәп телендә ир-атның җенес әгъзасын белдергән зәкәр сүзенә охшап кала.

[2] сәна – мактау.

[3] хифыз вазифасы – саклау вазифасы.

[4] үз тәдбире белән – үзе күргән чаралар ярдәмендә.

Икенчесе,– назым кәримнең мәгънәләрен бәян һәм тәблигъ[1] вазифасы,– өммәтнең үз тырышлыгына, хәсән ихтыярына тәслим кыйлынып, ачык, гомуми бер бәйге мәйданы кебек булды.

Хәятнең, фикернең хәрәкәтләрен табигый хәлләрендә калдыру өчен булса кирәк, икенче вазифа хакында Шаригъ кәрим хосусый тәдбирләр кормады, бәлки телнең дәляләтенә, өммәтнең фәһеменә игътимад итте[2]. Шуңа күрә әсхаб кирам гасырында, табигыйн арасында, әһле гыйлем, әһле әдәп арасында байтак мөфәссирләр[3] зоһур итте[4]. Шуңа күрә, тәфсир хосусларында мәзһәб юк иде, тәкълид юк иде. Шуңа күрә «Баб әт-тәфсир мәсдүд»[5] булмады, тәфсир капкалары янына сакчы куелмады.

Бу киңлек, бу хөррият безнең өчен гаять бөек бер бәрәкәт булды: әгәр берәү айәт кәримәне тәфсир иткәндә риваятьләр тәэсире белән, кәлам ысулы белән, мәзһәб кагыйдәләре белән айәт кәримә мәгънәләрен үзгәртсә, бозса, башка бере ул җитешсезлекне уртага куеп, тәнкыйть итә алу мөмкинлегенә ия булып кала.

<...>

Тилавәт тик гарәп телендә башкарыла.

Исламиятнең иң мөһим рөкене Коръән кәримнең гарәби назымыдыр, ягъни гарәп телендә булуыдыр. Ләкин Коръән кәримнең мәгънәләрен өммәтнең һәр әгъзасына бәян итү өчен, аны һәр мөселманга ирештерү – тәблигъ өчен, Коръәнне тәрҗемә итү, әлбәттә, фарыздыр.

Коръәнне тәрҗемә итүдә мин түбәндәге нәрсәләргә нигезләндем:

1. Әһле гыйлем каләме белән язылган тәфсирләр.

---

[1] тәблигъ – ирештерү, тарату, аңлату.

[2] игътимад итте – таянды.

[3] мөфәссир – Коръәнне тәфсир кыйлу белән шөгыфльләнә торган галим.

[4] зоһур итте – күренде, барлыкка килде.

[5] «Баб әт-тәфсир мәсдүд» – «Тәфсир капкасы ябылган».

Минем шәхси китапханәмдә тәфсирләрнең һәммәсе бар. Бер айәт кәримәне тәрҗемә иткәндә, тәфсирләрнең һәр беренә мөрәҗәгать иттем. Моны эшләгән сәгатьләрдә мин һич гамьсезлек кыйлмадым. Авырлыкларның уннан тугызы тәфсирләрнең бәрәкәте белән җиңел булды.

2. Коръән кәримнең үзе.

Айәт кәримәләрне тәфсир иткәндә, яки тәфсирләрнең берен куеп, башкасына сайлаганда, мин «тәфсир би-л-китаб»[1] юлларын сайладым. Коръән кәримнең берсе икенчесенә охшаган айәтләре берсе икенчесен тәфсир итә.

3. Тәрҗемәдә минем иң нык нигезем телгә караган дәлилләр.

Кәлимә-сүзләрнең төзелешен, аларның кайсы сүз төркеменә караганлыгын дикъкать белән тикшердем. Кәлимәләрнең төзелешенә караган дәлилләрен сарыф[2] ярдәме белән тикшердем; һич чыгарма ясамастан сүзләрнең иң асыл, иң беренчел мәгънәләренә таяндым. Җөмләләрнең мәгънәләренә, сүзтезмәләрнең ихтимал булган мәгънәләренә һәрнәрсәдән артык игътибар иттем.

Мәсәлән: *«...вә иттибага-кә әл-әрзәлүнә»*[3], кебек җөмләләрдә ия белән хәбәрне тәгаен хосусларында сакланып эш иттем. *«Вә иттибага-кә»* ия булса, мәгънәсе бер, хәбәр булса – мәгънәсе башка була. Игърабчылар[4] «тегесе дә бусы да, ихтимал»,– дисәләр дә, минем карашымда ике ихтималның мәгънәләре арасында аерма зурдыр. Нәбиләренә үҗәтләнеп каршы торучылар ике мәгънәдән, әлбәттә, тик берсен күздә тотканнар. Мондый җөмләләрдә хәлнең, әйтелергә тиешленең дәлил итүе белән ике мәгънәдән берсен тәгаен итәм. Һәрберсе дә әйтелә алса, ул вакытта һәрберен раслыйм.

---

[1] тәфсир би-л-китаб – Коръәнне тәфсир иткәндә тәфсир өчен аның үзен файдалану, ягъни тәфсирне Коръәннең үзеннән чыгып ясау.

[2] сарыф – сүз ясалышы, морфология.

[3] Айәтнең тулы тәрҗемәсе: «Алар әйттеләр: «Сиңа иң мескеннәрнең ияргәнен күрә торып сиңа ышанырбыз мыни?» (26:11).

[4] игърабчылар – гарәп теле белгечләре.

«Мән» – «мә», кебек исемнәргә җөмлә бәйлек булса, мәгънәсе бер, сыйфат булса, мәгънәсе башка була. Мәсәлән: «мән җә'а-кә фа-лә-һү дирһәм»[1] мәсәлендә бәйлек мәгънәсе белән сыйфат мәгънәсе араларында зур аерма бар. Айәтләрне тәрҗемә иткәндә, ул аермалар турында мин яхшылап уйладым.

4. Кыйраәт ихтыйлафлары[2] булса, һәрберен игътибарга алам.

Кыйраәтләр кайчак кәлимәләрнең ясалышларында, кайчак шәкелләрендә, кайчак төрләнешләрендә берсеннән-берсе аерылып торалар. Әгәр дә андый ихтыйлафлар аркасында айәтләрнең мәгънәләре төрле булса, һәрберен кабул итәм. Чөнки төрле кыйраәтләр күпсанлы айәтләр кебектер.

5. Җөмлә берничә мәгънәләрне ихтимал итеп тә, ул мәгънәләрнең һәрбере күздә тотыла алса, ул мәгънәләрнең һәрберен бәян иттем.

Ихтимал ителгән мәгънәләрнең кайчак тик берсе генә, бәгъзан һәрбере күздә тотыла ала. Әгәр һәрбере дә әйтелергә тиеш булса, тәрҗемәдә һәрберен зикер итәм[3].

Бер җөмлә, гарәби[4] булганга күрә, берничә мәгънәләргә ачыктан ачык дәлиллек итсә, Коръән кәримдә гафләт[5] мөмкин түгелдер, шуңа күрә ул мәгънәләрнең һәрбере дә күздә тотыла. Мондый айәтләр Коръән кәримдә күп.

6. Могъҗизави тәртипне ислях кыйлуны, яхшыртуны дәгъваларга бервакыт та җәсарәт итмәдем[6].

---

[1] Әлеге гарәп мәсәленең тәрҗемәсе: «Синең яныңа бер дирһәм белән килүче», дә була ала: «Синең яныңа килүчегә бер дирһәм» дә була ала.

[2] ихтыйлаф – каршылыклы төрлелек.

[3] зикер итәм – искә алам.

[4] гарәби – гарәп телендә, гарәпчә.

[5] гафләт – биредә игътибарсызлык, белмәү мәгънәсендә.

[6] җәсарәт итмәдем – базмадым, кыймадым, батырчылык итмәдем.

Нәхүчеләр[1] Коръән кәрим айәтләрен игътибарга алмау һәм фараз кыйлу ысуллары белән ислях итәләр[2]. Бу гадәт тәфсирчеләрнең күбесендә бар.

Мәсәлән, *«вә изә әрадна ән нүһликә карьйәтән әмар-на мутрафи-һа фә-фәсику фи-һа»*[3] айәт кәримәсе кебек. Биредә әһле тәфсир «би-т-тагат» [«итәгать белән»,– А.Х.] сүзенең барлыгын фараз кыйлып «***әмар-на*** *би-т-тагати* ***фә-фәсику***» [ягъни «Аллаһка итәгать итүне әмер итәбез, ә алар бозыклык кыйлалар»,– А.Х.] дигәннәр. Мондый тәкъдирләр Коръәннең могъҗизави эчтәлеген тулысынча бозудыр. Миңа күрә: *«әмар-на мутрафи-һа»,* дигән гыйбарә «әмир итәбез мосрифләрен[4]» мәгънәсендәдер. Моңа *«вә кәзәликя җәгалнә фи*

[1] нәхүчеләр – синтаксис белгечләре.

[2] ислях итәләр – яхшырталар, дөресլиләр.

[3] Коръәннең 17:16 айәтенең бер өлеше. Г. Исаев тәфсирле тәрҗемәсендә болай яңгырый: «Әгәр дә Без бер шәһәрне һәлак итәргә телибез икән, аларның бөекләренә хәбәр бирәбез. Алар ул хәбәрне тыңламый икән, ул шәһәрне газап итәргә тиешле булып кала…» (Г. Исаев тәрҗемәсе). Айәтнең тәфсирсез тәрҗемәсе: «Без әгәр нинди дә булса бер карьяәне һәлак итәргә теләсәк, андагы рәхәт тормышка күнеккәннәргә әмер итәбез һәм алар анда бозыклык кыйла башлыйлар…».

[4] мосрифләр – исраф кыйлучылар, рәхәт тормышка күнеккән түрәләр, байлар, хәллеләр.

*күлли карьйатин әкәбира мужҗрими-һа»*[1] дигән айәт кәримә дә, *«аммәр-на»*[2] дигән мөтәватир[3] кыйраәт тә дәлаләт итә.

7. Кәлам[4] ысулларына, яңа һәм борынгы фәлсәфә карашларына Корьән айәт кәримәләренең дәлаләтләрен[5] тәтбыйкъ итү[6] кебек яманлыклардан сакландым.

8. Әһле тәфсирнең[7] күбесе я риваять тәэсире[8] белән, яки тәфсир итү теләге белән Корьәннең кабатланмас могъҗизави эчтәлегенең дәлаләтен бозып, кайчак айәт кәримәләрнең

---

[1] Корьән, 6:123: «Шулай итеп, Без һәрбер шәһәрдә, авылларда җинаятьчеләрен олугларын кылдык…» (Г. Исаев тәрҗемәсе). Дөрес тәрҗемә: «Шулай итеп, Без һәр карьянең олугларын шул карьянең җинаятьчеләре кыйлдык».

[2] Димәк, 17:16 айәтнең мәгънәсен Муса Җаруллаһ түбәндәгечә аңлата: айәттәге (أَمَرْنَا) әмәрнā (Інче баб үткән заман) фигыле хәрәкәләр куелганчы II нче баб фигыле булып (أَمَّرْنَا) әммәрнā, дип яңгыраган һәм бу сүзнең шундый укылышы (кыйраәте) дә сакланган имеш. Хәрәкәләр куелмаган очракта әлеге ике фигыльнең язылышында тышкы аермалар юк, икесе дә امرنا буларак языла. Болай булганда, М. Бигиевнең фикеренчә, фигыльне «без әмер иттек», дип түгел, «Без әмир иттек», дип тәрҗемә итә. Бигиевнең бу фикерне ныгыта торган ике дәлиленә өстәп тагын ике дәлил китереп була: мутрафӣ-һā дигән сүзтезмәнең килеше идарә итүче II нче баб әммәрнā (أَمَّرْنَا) («әмир иттек», «түрә иттек») фигыле белән яраша, ә I нче баб әмәрнā (أَمَرْنَا) («әмер иттек», «боердык») фигыле белән ярашмый; икенчедән, аммарнā фигыленең яңгырашы шул ук айәттә соңрак килгән дәммәрнā («җимердек») фигыленең яңгырашына туры килеп, Корьәнгә хас шигъри аһәңне булдыра.

[3] мөтәватир – ышанычлы, шиксез, өзлексез рәвештә буыннан буынга тапшырылып килгән.

[4] кәлям – ислам дини фәлсәфәсенең бер төре. Муса Бигиев карашынча, кәлямда бик күп уйдырмалар булуы сәбәпле, ул мөселманнарның иманнарына, гакыйдәләренә зыян китергән.

[5] дәлаләт – дәлилләр; дәлил итү, дәлил булу.

[6] тәтбикъ итү – туры китерерү, куллану.

[7] әһле тәфсир – Корьән айәтләренең мәгънәләрен, эчтәлеген аңлату белән шөгыльләнгән дин галимнәренең уртак атамалары.

[8] риваять – буыннан-буынга тапшырылып килгән дини һәм тәрбияви эчтәлекле хикәяләр. Биредә хәдисләр дә, сәхабәләр һәм аларның шәкертләреннән калган хатирәләр дә күздә тотыла.

мәгънәләрен тәхриф итәләр[1]. Мәсәлән, *«...фә-изә һиййә тәлкафу мә йәэфикунә»[2]; «...тәлкаф мә санагу...»[3]* кебек айәт кәримәләрне: «таяк бауларны йотты» дип тәрҗемә итүләрен алыйк. Мондый тәфсир яки тәрҗемә, беренчедән, Коръән кәримне тәхриф итү, бозу була; икенчедән, ул *«фә-вәкага-л-хакку вә баталә мә кәнү йәгъмәлүнә»[4]; «иннәмә санагу кәйдү сәхирин»[5]* кебек айәт кәримәләрнең ачыктан-ачык дәлилләренә туры килми.

[1] тәхриф итәргә – техник төшенчә (термин) буларак тәхриф теләсә нинди сәмави китаптагы (Тәурат, Зәбур, Инҗил, Коръән) нинди дә булса сүзнең мәгънәсен үзгәртү өчен андагы хәрефләрнең урыннарын алмаштыруны белдерә: «Яһүд булып киткәннәр арасында шундыйлар да бар ки, алар [Аллаһ] сүзен [ягъни Тәүратның айәтләрен] тәхриф кыйлалар да: «Без ишеттек һәм гыйсьян кыйлдык» – диләр» (4:46); «алар [Аллаһ] сүзен [ягъни Тәүратның айәтләрен] тәхриф кыйлалар...» (5:13). М. Бигиевнең китабында исә, сүз Коръән айәтләренең мәгънәләрен үзгәртү һәм бозу турында бара. Шул рәвешле, Муса әфәнде бик яман гөнаһка ишарә итә, чөнки изге китапларның мәгънәләрен бозу Коръәнгә кадәр иңгән китапларга карата гына булмаган, хәтта Коръәннең үзенә карата да булган: «Аларның сезгә ианууларын телисезмени, мәгәр алардан бер төркем бар ки, Аллаһның сүзен ишеттеләр дә, аның мәгънәсен аңлый торып аннары аны тәхриф кыйлдылар» (2:75); «алар [Аллаһ] сүзен [ягъни Коръән айәтләрен] дә тәхриф кыйлалар» (5:41); «Үз куллары белән китапны язып, анан соң аның бәрабәренә аз гына акча казану өчен: «Бу Аллаһ тарафыннандыр!», диючеләргә һәлакәт һәм үкенечтер! « (2:79).

[2] Коръән, 26:45. Г. Исаев тәрҗемәсе: «...шунда сихерчеләрнең уйлап чыгарган нәрсәләрен йотты»; Ногмани тәфсире: «...шулвакыт зур елан булды да тегеләрнең сихер белән елан итеп күрсәткән аркан вә таякларын чәйнәп ашап бетерде».

[3] Коръән, 20:69. Г. Исаев тәрҗемәсе: «...алар китереп чыгарган нәрсәне йотар»; Ногмани тәфсире: «аларның сихер белән елан итеп күрсәткән җепләрен вә таякларын ашасын».

[4] Коръән, 7:118. Г. Исаев тәрҗемәсе: «Шулай итеп, турылык өскә чыкты, ялган сихерләре юкка чыкты»; Ногмани тәфсире: «Хаклык өскә чыгып аларның сихергә таянып эшләгән ялган эшләре батыл булды – юкка чыкты».

[5] Коръән, 20:69. Г. Исаев тәрҗемәсе: «алар эшләгән нәрсәләр –

*«Тәлкафу мә йәэфикүнә»; «тәлкаф мә санагу»* дигән җөмләләрдә «таяк бауларны, таякларны йотты» мәгънәсенә дәлил була алырлык бер хәреф тә юк.

Сихерчеләрнең сихер куәте белән бауларга, таякларга елан сурәтләре бирелгән кебек булса, хыял күзенә күренгән ул сурәтләр Мусаның кулында булган таякның бәрәкәте белән юкка чыгарылган булганга күрә ул таяк шул сурәтләрне йотмыш кебек булса: «таяк бауларның, таякларның үзләрен йотты»,– дип әйтү Коръәннең кабатланмас могъҗизави эчтәлеген тәхриф була, бозу була.

Мондый мисаллар тәфсирләрдә күп. Мин тәрҗемәмдә андый мисалларның берсен генә булса да ислях итә[1] алган булсам әгәр, берничә еллык тырыш хезмәтемнең әҗере хасыйл булды, димәк. Әгәр инде андый мисалларның йөзен, я тагын да артыгын ислях кыйлу шәрәфенә ирешсәм, тәрҗемәмне нәшер итмәк минем өчен фарыз булды, дип әйтеп булачак.

Ислях сүзен бары тик вак-төяк һәм җиңел хаталарга нисбәтән кулландым. Юкса, «әл-Әнгам» сүрәсендә *«вә ләләбәсна галәй-һим мә йәлбисүнә»* дигән могъҗиз назымны «һәм аны алар кигән кием белән капладык» дигән сүз белән тәфсир иткән «Мәвакиб» кебек телне белмәгән җаһилләрнең каләме белән язылган тәфсирләрдә булган бихисап фахиш[2] хаталар хакында ислях сүзе әйтелмәс.

«Дар-е сәгадәт»тә «Мәҗлис-е тәфтиш-е Мәсахиф-е шәрифә»[3] мөһерләре белән табыгъ кыйлынмыш[4] Коръән кәримнең кырларында андый тәфсирләрне күргәндә күңел тәэсирләнә.

Усул-ы фикъһы[5] һәм фикъһы буенча хезмәтләр язган, табигать, сәясәт, икътисад, хокук кебек фәннәрдә бөек китаплар

---

сихерче хәйләсе»; Ногмани тәфсире: «аларның ясаган еланнары сихерченең хәйләседер».

[1] ислях итү, кыйлу – төзәтү, дөресләү.

[2] фахиш – коточкыч, котны ала торган, тупас, яман.

[3] «Мәҗлис-е тәфтиш-е Мәсахиф-е шәрифә» – «Изге Мосхәфләрне тикшерү мәҗлесе».

[4] табыгъ кыйлынмыш – бастырылган, басылып чыккан.

[5] усул-ы фикъһы – фикъһы гыйлеменең методологик нигезләре.

тәэлиф иткән Мәхмүд Әсгад[1] әфәнде хәзрәтләренең «Мәдхал -и тарих-и ислам»[2] исемле китабында (12 нче фасыл, 54 нче маддә, 118 нче сәхифә) дә «вә үз киемнәре белән киендерер идек» дигән тәфсирен дә күрсә, «Мәҗлис-и тәфтиш-и Мәсахиф шәрифә» мөһерендә булган хаталарны да мәгъзур[3] күрер. Ләкин ислам галәмендә әдәпнең, диннең ул кадәр түбән төшүенә күңел яна.

9. Тәрҗемәдә һичбер айәт кәримәдә тәфсир, я тәэвил[4] юлларына авышмадым.

Тәфсир, тәэвил нинди генә булса да, ул, асылда, теге яки бу кешенең фикере генә була. Тәрҗемәдә мин Коръән кәримнең бары тик горефләрен[5], гарәп теленең дәлаләтләрен игътибарга алдым, бер генә булса да хәрефкә карата һичбер кешенең карашын нигез итеп алмадым. Коръән кәримнең бөек мөкаддәс мәгънәләрен үземнең вак һәм гади фикерләрем белән бергә язуда, мин, әлбәттә, читләшәм. Андый хиррифләргә[6] Аллаһның, мәләкләренең[7] вә һәммә кешеләрнең ләгънәтләренә кушылып мин дә ләгънәт укыйм.

10. Коръән кәримнең мәгънәләре, эчтәлеге кебек үк, ныклап теркәлгәннәр. Шуңа күрә аны тәрҗемә итү мөмкин.

Коръән кәримнең һәрбер кәлимәсе, хәрәкәләре-сөкеннәре[8] белән, ничек сакланып калган булса, кәлимәләрнең,

[1] әсгад (гарәп.: иң бәхетле) – әлеге исем татар телендә Әсхәт буларак кулланыла.

[2] «Мәдхал-и тарих-и ислам» – «Ислам тарихына кереш».

[3] мәгъзур – гафу ителә торган, акланыла торган.

[4] тәэвил – Коръән айәтләренең мәгънәләрен ачыклау нияте белән өстәмә аңлатмалар бирү.

[5] гореф – гадәт. Биредә Коръәннең контексты, гомуми рухы күздә тотыла.

[6] хирриф – асыл мәгънәне бозучы, үзгәртүче.

[7] мәләкләренең – фәрештәләренең.

[8] хәрәкәләр-сөкеннәр – гарәп язуында кыска сузык авазлар (ә-а, и-ы, ү-у авазлары) хәреф буларак күрсәтелми. Андый авазларны белдерер өчен язылган сүзгә хәрәкәләр, ягъни сүзнең әйтелешен төгәл күрсәтә торган махсус билгеләр куела. Сөкен дә – шундый хәрәкәләрдән булган бер билгенең исеме. Ул йомык авазны, ягъни тартык аваз белән тәмамланган иҗекне белдерү өчен кулланыла.

җөмләләрнең мәгънәләре дә шулай саклангән. Ислам каләме белән тәэлиф кыйлынып[1] ислам гыйлемнәренә багышланган китаплырның һәрбере Коръән кәримнең җөмләләренең мәгънәләрен үзгәрешсез хәлдә саклау өчен генә иде. Тел белеменә караган китаплар, сарыф китаплары, нәхү китаплары, бәлягать китаплары, фикъһы китаплары, ысул-и фикъһы китаплары – кәлимәләрнең, җөмләләрнең мәгънәләрен үзгәрешсез хәлдә саклау өчен булган иде.

Мәгъсум[2] ислам өммәтенең тырышлыгы белән Коръән кәримнең һәм эчтәлеге, һәм мәгънәсе үзгәрешсез хәлдә теркәлде.

Мәгънәсе дә эчтәлеге кебек саклангән икән, Коръән кәримне тәрҗемә зарури сурәттә мөмкин була, «мәгънәсе сакланган хәлдә дә тәрҗемә итү мөмкин түгелдер», дип әйтү ул: «Коръән кәримнең мәгънәләре һичбер вакыт аңлашылмаячак»,– дип әйтү кебектер.

Кайчак бер җөмләдән үк аңлашыла торган мәгънә, гасырлар узгач, яки өммәтнең горефләрендә үзгәрешләр барлыкка килүе аркасында, төрле була. Шул сурәттә хәрфиян тәрҗемә[3] дөрес булмас. Горефтән, я әүвәлге мәгънәсеннән гафил булган кеше тәрҗемә итсә, хата кыйлыр. Мәсәлән: горефебездән гафил булган гарәпләрнең беренә «котым очты» сүзен «рух-и тарат» җөмләсе белән тәрҗемә итәр исәк, хата кыйлган булырбыз.

Кайчак шулай була ки, җөмләләрнең мәгънәләре мөхтәлиф булмаса да, ул мәгънәләр нигезендә барлыкка килгән күзаллаулар, сурәтләр мөхтәлиф була. Хәлләре яки хыяллары төрле дәрәҗәдә булган ике кеше бер үк җөмләне ишеткәндә, андагы бер мәгънә ул ике адәмнең миләрендә мөхталиф ике сурәт белән ихата кыйлыныр. Берсенең хыялында, бәлки,

[1] тәэлиф кыйлынган – язылган, төзелгән. Тәэлиф төшенчәсе китап язуның аны төзүдән яки иҗат итүдән гыйбарәт булган бер ысулын белдерә.

[2] мәгъсум – саф, гыйффәтле, гөнаһсыз.

[3] хәрфиян тәрҗемә – сүзнең мәгънәсен тышкы кыяфәтенә (күренеп торган мәгънәсенә) генә таянып аңлау һәм тәрҗемә итү.

гаять дәһшәтле, икенчесенең хыялында, бәлки, гаять гади сурәт бар була. Шуңа күрә, бер җөмлә берәүгә тәэсир итә, башка берәүгә тәэсир итми. Шуңа күрә, роман, шигырь кебек әдәби әсәрләрнең тәрҗемәләре кайчак асыллары кебек була алмый, чөнки кәлимәләрнең мәгънәләре, бәлки, дөрес тәрҗемә кыйлынган булса да, шагыйрьләрнең хыял куәте белән тасвирланган сурәтләрне тәрҗемәче әфәнде тиешенчә тасвирлый алмый. Шуңа күрә тәрҗемә рухсыз булып чыга. Яки һич тә мөмкин булмый, чөнки лисан ишетүче яки укучыга коры мәгънәләрне генә җиткерә, әмма хыял күкләрендә тәэсир куәте белән оча торган сурәтләрне ауламактан кайчак гаҗиз була.

Мәгънәләрнең һәм сурәтләрнең төрлелекләре аркасында, тәрҗемә кайчак мөмкин булмый дидек. Дөрес, ләкин Коръән кәрим кәлимәләренең җөмләләренең мәгънәләре та Кыямәт[1] сабиттыр, алар хыял сурәтләре түгел, бәлки хакыйкатьтер. Шуңа күрә Коръән кәримне тәрҗемә катгый сурәттә мөмкиндер, шәригать күзлегеннән бакканда хәтта фарыздыр.

Мең телгә тәрҗемә кыйлынсын, ул мәхфуз[2] һаман!

---

[1] та Кыямәт – Кыямәткә кадәр, Кыямәт башланганчы.

[2] мәхфуз – сакланыла торган; саклануы.

# Маъидә[1]

Ошбу китап – кешеләрнең аш-сулары, табыннары хакында Коръән кәримнең айәт кәримәләрен, ислам диненең өйрәтүләрен иҗтиһад юлы белән бәян итә торган китап. Корбан мәсьәләләре дә биредә соң дәрәҗәдә катгый рәвештә хәл ителә.

(هُوَ الَّذِي خَلَقَ لَكُم مَّا فِي الأَرْضِ جَمِيعاً) (әл-Бәкара сүрәсе, 29)[2]

(فَأَنشَأْنَا لَكُم بِهِ جَنَّاتٍ مِّن نَّخِيلٍ وَأَعْنَابٍ لَّكُمْ فِيهَا فَوَاكِهُ كَثِيرَةٌ وَمِنْهَا تَأْكُلُونَ) (әл-Мөэминүн сүрәсе, 19) [3].

(وَالأَنْعَامَ خَلَقَهَا لَكُمْ فِيهَا دِفْءٌ وَمَنَافِعُ وَمِنْهَا تَأْكُلُونَ) (ән-Нәхел, 5) [4].

*Бисмиллаһи-р-рахмани-р-рахим*

(يَسْأَلُونَكَ مَاذَا أُحِلَّ لَهُمْ قُلْ أُحِلَّ لَكُمُ الطَّيِّبَاتُ) (әл-Маъидә, 4) [5].

Кешенең табынында азык-төлек кебек, эчемлек кебек иң зарури хаҗәтләренә кагылышлы гаять мөһим сорауның иң хикмәтле, иң тулы җавабы Коръәннең «Маъидә» исемле 5 нче сүрәсендә, шуның да 4 нче айәтендә илаһи кайгыртучанлык теле белән бәян ителгән. Әмма, шул ук сүрәнең алдагы 3 нче

---

[1] Чыганак: Муса Җаруллаһ. Маъидә. СПб.: Тип. М-А. Максутова. 34 б. (Әсәр госманлы-татар һәм гарәп телләреннән тәрҗемә ителде; астөшермәләр, Коръән айәтләренең тәрҗемәләре төзүче тарафыннан ясалды).

[2] «Ул җир йөзендә булган нәрсәләрнең барысын да сезнең өчен барлыкка китерүчедер» (2:29). Муса Бигиев әсәрендә китерелгән Коръән кәрим айәтләре автор тарафыннан тәрҗемә ителмәгән очракларда, тәрҗемәләре А. Хәйретдинов башкаруында бирелде.

[3] «(күктән яуган яңгыр) белән Без сезнең өчен хөрмә белән йөзем бакчалары үстердек. Аларда сезнең өчен күп җимешләр бар, һәм дә сез шуларны ашыйсыз» (23:19).

[4] «Һәм терлек,– Ул аны сезнең өчен барлыкка китерде. Анда җылыну белән төрле файдалар, һәм сез шулар белән тукланасыз да» (16:5).

[5] «Аларга нәрсәләрнең хәлал ителгән булуы турында синнән сорыйлар. «Сезнең өчен яхшы нәрсәләр хәлал ителде»,– дип әйт» (5:4).

айәтендә ашарга яраксыз, ягъни, хәрам булган унбер нәрсә искә алына.

Табигый ки, берәү хәрам азык-төлек турында укыганнан соң шундук хәлал булган нәрсәләр турында да, әлбәттә, тәфсилле аңлатма таләп итәчәк иде. Шуңа күрә, шул туачак сорауга җавап буларак иңгән 4 нче айәттә Коръән ашарга яраклы, ягъни, хәлал булган нәрсәләрне «яхшы ашамлыклар» мәгънәсенә ия булган *таййибат* сүзе белән белдереп, хәрамның нигә хәрам булуын, хәлалнең нигә хәлал булуын да аңлатып биргән. Асылда, хәлалнең хәлал булуы аның яхшы ашамлык булуыннан килгән кебек, хәрамнең дә хәрам булуы, ягъни тыелуы, әлбәттә, аның *хәбис*, ягъни, начар нәрсә булуыннан килә.

Әлеге хакыйкать мөэминнәрнең игътибарына Коръәннең күпсанлы айәтләрендә тәкъдим ителгән иде, мәсәлән: (يَا أَيُّهَا الَّذِينَ آمَنُواْ كُلُواْ مِن طَيِّبَاتِ مَا رَزَقْنَاكُمْ وَاشْكُرُواْ لِلّهِ إِن كُنتُمْ إِيَّاهُ تَعْبُدُونَ) (әл-Бәкара сүрәсе, 172).

Ягъни, Коръәндә: «*Йийеңез сезә ихсан кыйлынмыш ризыклардан ялңыз таййибләрене. Тәгамеңези ялңыз таййибатә хасыр кыйлыңыз*»[1],– диелгән.

(يَا أَيُّهَا الَّذِينَ آمَنُواْ لاَ تُحَرِّمُواْ طَيِّبَاتِ مَا أَحَلَّ اللّهُ لَكُمْ وَلاَ تَعْتَدُواْ إِنَّ اللّهَ لاَ يُحِبُّ الْمُعْتَدِينَ وَكُلُواْ مِمَّا رَزَقَكُمُ اللّهُ حَلاَلاً طَيِّبًا وَاتَّقُواْ اللّهَ الَّذِيَ أَنتُم بِهِ مُؤْمِنُونَ) (әл-Маъидә, 87).

Ягъни: «*Аллаһ сезә хәлал итмеш таййибати тәхрим итмәңез. Таййибати хәрам итмәк хәбаъиси*[2] *хәлал итмәк кеби игътида улур. Мөгътәдиләри Аллаһ сәүмәз. Хәлал улмак* *<u>үзрә сезә Аллаһ</u> ихсан итмеш ризыклари йийеңез*»[3].

[1] Әлеге җөмлә Муса әфәнде Бигиевнең китабында ничек язылган булса, шулай бирелде. Аның хәзерге татар теленә тәрҗемәсе: Сезгә мәрхәмәт йөзеннән бирелгән ризыклардан бары тик яхшыларын ашагыз. Аш-суыгызны аларның бары тик яхшылары белән чикләгез.

[2] хәбаъис – шакшы нәрсә; ашарга-эчәргә яраксыз булган нәрсә.

[3] Әлеге җөмлә Муса әфәнде Бигиевнең китабында ничек язылган булса, шулай бирелде. Аның хәзерге татар теленә тәрҗемәсе: Аллаһ сезгә хәлал иткән яхшы нәрсәләрне хәрам кыйлмагыз. Яхшы нәрсәләрне хәрам итү шакшы нәрсәләрне хәлал итү кебек хәттин ашу була. Аллаһ хәттин ашучыларны сөйми. Аллаһ сезгә мәрхәмәт йөзеннән хәлал итеп биргән ризыкларны ашап туклаңыгыз.

Мәгънәсе: Ашарга яраклы бер яхшы нәрсәне хәрам итү тыела. Нинди дә булса начар бер нәрсәне ашау тыела.

(قُلْ مَنْ حَرَّمَ زِينَةَ اللهِ الَّتِيَ أَخْرَجَ لِعِبَادِهِ وَالْطَّيِّبَاتِ مِنَ الرِّزْقِ قُلْ هِي لِلَّذِينَ آمَنُواْ فِي الْحَيَاةِ الدُّنْيَا خَالِصَةً يَوْمَ الْقِيَامَةِ) (әл-Әгъраф, 32).

Ягъни: «*Кем хәрам идә белүр Аллаһның у зиннәтләрене ки, бәндәләренә вирмеш? Кем хәрам идә белүр ризыкның у таййибләрене ки, бәндәләренә Аллаһ ихсан итмеш? Кыямәтдә һичбер мөэхазәсе улмамак үзрә у таййибатдән, у зиннәтдән әһле иман истифадә идәр*»[1].

Әгәр дә яхшы нәрсәләрнең хәрам булуы, яки хәрамнең яхшы нәрсә булуы мөмкин булса иде; кием-салым кебек зиннәтләрдән, азык-төлек кебек хәлал ризыклардан баш тарту очракларына кагылышлы әлеге күләмле илаһи нотык иңмәс иде.

(يَأْمُرُهُم بِالْمَعْرُوفِ وَيَنْهَاهُمْ عَنِ الْمُنكَرِ وَيُحِلُّ لَهُمُ الطَّيِّبَاتِ وَيُحَرِّمُ عَلَيْهِمُ الْخَبَآئِثَ وَيَضَعُ عَنْهُمْ إِصْرَهُمْ وَالأَغْلاَلَ الَّتِي كَانَتْ عَلَيْهِمْ) (әл-Әгъраф, 157) [2].

Исламиятнең әүвәлге өммәтләргә зур игътибар бирүен Коръән кәрим әлеге айәт кәримәдә чагылдырганда, иң зур әһәмияткә ия булган өч нәрсә арасында, һәр яхшы нәрсәнең хәлаллеге, һәр шакшы, һәр начар нәрсәнең хәрамлеге да искә алынган.

Ислам шәригатендә яхшы нәрсәләр җөмләсеннән булган һәр әйбер хәлалдер; хәрамлек, ягъни тыелган булу, бары тик теге яки бу нәрсәгә хас булган начарлыкка, яманлыкка кайтып кала. Әмма, әүвәлге өммәтләрнең кайберләре яхшы булган нәрсәләрнең кайберләрен, яки күпчелеген үзләре өчен хәрам итәләр иде. Мәсәлән: Һиндннең браһманнары буддалары кебек,

[1] Әлеге җөмлә Муса әфәнде Бигиевнең китабында ничек язылган булса, шулай бирелде. Аның хәзерге татар теленә тәрҗемәсе: Аллаһның бәндәләренә биргән зиннәтләрен кем хәрам итә ала? Аллаһ бәндәләренә рәхмәт йөзеннән ризык итеп биргән яхшы нәрсәләрне кем хәрам итә ала? Иман ияләре ул яхшы нәрсәләрне, ул зиннәтләрне кыяматтә һичбер шелтә-гаепләүгә дучар ителмәстән файдаланалар. Айәтнең татар теленә тәрҗемәсе белән Муса Бигиевнең аны аңлавы арасында аерма бар.

[2] «(Пәйгамбәр) аларга игелек кыйлырга боера һәм начарлыкларны тыя, алар өчен яхшы нәрсәләрне хәлал итә вә шакшы нәрсәләрне хәрам итә, дучар ителдекләре кыенлыклардан вә өсләрендә салынган богаулардан аларны азат итә» (7:157).

нәсаранияттнең раһиблары[1], кяһиннары[2] кебек, яһүдиләрнең һәммәсе кебек.

Бервакыт Исраил хәзрәтләре, ягъни хөрмәтле Йагъкуб пәйгамбәр үзенең хәстәлегеннән дәвалану максаты белән булса кирәк, табипларның киңәшләрен үтәп, дөя ите, дөя сөте кебек кайбер ризыкларны үзе өчен хәрам иткән булган. (كُلُّ الطَّعَامِ كَانَ حِـلاًّ لِّبَنِي إِسْرَائِيلَ إِلاَّ مَا حَرَّمَ إِسْرَائِيلُ عَلَى نَفْسِهِ مِن قَبْلِ أَن تُنَزَّلَ التَّوْرَاةُ) (Ал-е Гыймран, 93) [3].

Айәтнең тәфсире болайдыр: Тәүрат китабы иңгәнче, ягъни, Нух пәйгамбәрнең шәригатендә һәм Ибраһимның пәйгамбәрнең шәригатендә һәрбер ризык Исраил токымына хәлал иде. Исраил хәзрәт үзе, бары тик үзе өчен генә, кайбер ризыкларны хәрам иткән иде. Хәстәлек сәбәбе белән генә хәрам кыйлынган ризык хөрмәтле Исраил пәйгамбәрнең үзенә дә, балаларына да асылда, әлбәттә, хәлал иде.

Кызып китү, ачу чыгу аркасында яки нәзер әйтеп адарыну сәбәбе белән теге яки бу нәрсә вакытлы сурәттә, әлбәттә, хәрам кыйлына ала. Ләкин, андый ясаклану билгеле вакыт белән чикләнелгән була; андый хәрам авыру кешенең бары тик үзенә генә кагыла. Әмма, Исраилнең угыллары, үзләренең олуг аталары Исраилне ихтирам итүләре йөзеннән булса кирәк, дөя итен, дөя сөтен Исраил кавеменә хас булган бер гадәт рәвешендә үзләренә дә хәрам кыйлдылар. Заманнар үтә торды, әлеге вакытлы ясак акрынлап милли сөннәт булу дәрәҗәсенә ирешә. Башта үзләренең ихтыярлары белән үзләренә йөкләнгән һәм дәвамлы булу аркасында милли гадәт булып киткән әлеге ясак ахырда күктән иңгән шәригатьнең фәрманы белән яһүдиләргә фарыз буларак йөкләнде.

Бер өммәтнең милли сөннәтендә, борынгы гадәтендә дини яки иҗтимагый бер зарар булмаса, *сәмави*[4] шәригать андый

[1] раһиб – монах.

[2] кяһин – дини йола үтәүче дин әһеле.

[3] «Тәурат иңдерелгәнгә кадәр Исраилнең үзенә үзе хәрам кыйлган тәгамнәрдән кала Исраил токымы өчен ашамлыкларның һәммәсе дә хәлал иделәр» (3:93).

[4] сәмави (гарәп. сәма’ – күк) – күктән иңгән, илаһи.

сөннәтләрне, андый гадәтләрне кабул итә ала. Сәмави шәригатьнең күпчелек хөкемнәре – өммәтнең матур гадәтләреннән, мәсълихәтле-файдалы горефләреннән алынган күчермәдер. Кайчак ул хөкемнәр өммәтнең хаҗәтләренә күрә тармакланып та китәләр. Ягъни, бер өммәт үзенең ихтыяры белән үзенә бер гадәтне тиешле нәрсә буларак йөкләсә, ул гадәттә зур бер зарар булмаса, сәмави шәригать аны да гадәткә кертергә ярдәм итә. Яһүдиләрнең шәригатьләрендә мондый хәлләрнең шаһитләре байтак. Яһүдләр очрагында дөя итен, дөя сөтен ясаклау мәсьәләсе дә моның ап-ачык шаһиты.

«Ән-Ниса» сүрәсенең 160 нчы айәт кәримәсендә Коръән болай диеп боерган: (فَبِظُلْمٍ مِّنَ الَّذِينَ هَادُواْ حَرَّمْنَا عَلَيْهِمْ طَيِّبَاتٍ أُحِلَّتْ لَهُمْ)[1].

Яһүдиләргә хәлал кыйлынган яхшы нәрсәләрне, үзләренең карарларына күрә, хәрам кыйлдык. Яхшы нәрсәләрне ясаклау Безнең илаһи хикмәтебезгә мөнасыйп булмаса да[2], бер өммәтнең үз өстенә алган гадәтләрне раслау юлы белән, ул яхшы нәрсәләрне яһүдиләр өчен хәрам иттек. Үз-үзләренең хәлләрен кыенлаштыру, үз-үзләрен көчләү ягыннан яһүдиләрнең өсләренә алган бу йөкләмәләре золым иде, гаделсезлек иде. Бу йөздән, башта хәлал булган ул яхшы нәрсәләрне Шәригъның[3] ясаклавы да бер җәза иде.

«Әл-Әнгам» сүрәсенең 146 нчы айәт кәримәсендә Коръән болай диеп боерган: (وَعَلَى الَّذِينَ هَادُواْ حَرَّمْنَا كُلَّ ذِي ظُفُرٍ وَمِنَ الْبَقَرِ وَالْغَنَمِ حَرَّمْنَا عَلَيْهِمْ شُحُومَهُمَا إِلاَّ مَا حَمَلَتْ ظُهُورُهُمَا أَوِ الْحَوَايَا أَوْ مَا اخْتَلَطَ بِعَظْمٍ ذَلِكَ جَزَيْنَاهُم بِبَغْيِهِمْ وِإِنَّا لَصَادِقُونَ)[4].

---

[1] «Яһүдиләр кыйлган золым аркасында Без элек алар өчен хәлал булган яхшы нәрсәләрне хәрам иттек» (4:160).

[2] мөнасыйп булмаса да – туры килмәсә дә; ятышлы булмаса да; килешмәсә дә.

[3] Шәригъ – шәригать кануннарын булдыручы, биредә – Аллаһ Тәгалә күздә тотыла.

[4] «Яһүдиләр өчен тояклы терлекнең барысын да хәрам кыйлдык. Сыер вә сарыкның сыртындагы, эчәкләрендәге һәм сөякләрендәге майдан кала башка майларын алар өчен хәрам иттек. Буйсынмаулары сәбәпле аларны шулай җәзаладык. Дөресен әйткәндә, Бездер дөреслек кыйлучылар» (6:146).

Ягъни: «*Йәһүдләрнең бәгыйләренә, золымларына җәза улмак үзрә, шу таййибати йәһүдләрә хәрам итдек. Юкса, у таййибат Нухның Ибраһимның шәригатьләрендә йәһүдләрә хәлал иде*[1]».

Бу ике айәтнеңраслауларына күрә, өммәтнең үз өстенә алган йөкләмәләре өчен, үз-үзләрен көчләүләре, мәҗбүр итүләре өчен җәза буларак, яхшы нәрсәләр хәрам ителә ала. Андый сурәтләрдә теге яки бу нәрсәнең хәрамлеге аның асылда начар нәрсә, ягъни хәбис булуыннан килми, бәлки җәзаның бер төре булуыннан килә.

Безнең ислам шәригатендә нәрсәне дә булса җәза буларак хәрам кыйлу очраклары юк. Исламияттә хәрамлекнең сәбәбе бары тик начарлыктыр. Бу йөздән, исламияттә хәрам буларак танылган һәрнәрсә, әлбәттә, начардыр.

Нинди дә булса бер нәрсәдә кешенең я бәдәненә, я диненә зарар бирә алырлык сыйфат бар икән, ул әйбер, әлбәттә, начар, ягъни хәбис була. Мәсәлән, үләксә начардыр, кан начардыр, чөнки кешенең бәдәненә зыян китерә ала. Тагутларның[2] берсенә атап чалынган хайван хәбистер, чөнки болай итү кешенең диненә, тәүхиденә зарар бирә.

Димәк, һәр начар нәрсә, һәр хәбис хәрамдер. Андыйларны ясаклау, хәрам кыйлу – я бәдәненә, я диненә зыян китерә алган нәрсәләрдән кешене химая кыйлу, саклау чарасы буларак кабул ителгән.

Хәлал булган һәр ашамлык, әлбәттә, яхшы нәрсә була, пакь була, саф була.

Нинди дә булса бер нәрсә кешенең бәдәненә я азык, я дәва булып, һичбер яктан да зарарлы булмаса, ул нәрсә, Коръән бәяләвенчә, яхшы, пакь нәрсә була.

[1] Әлеге җөмлә Муса әфәнде Бигиевнең китабында ничек язылган булса, шулай бирелде. Аның хәзерге татар теленә тәрҗемәсе: Йәһүдләрнең буйсынмаулары, золым кыйлулары өчен җәза буларак, ул яхшы нәрсәләрне йәһүдләргә хәрам иттек. Юкса, ул яхшы нәрсәләр Нухның да, Ибраһимның да шәригатьләрендә йәһүдләр өчен хәлал иделәр.

[2] тагут – потпәрәстләрнең, ягъни потларга табынучыларның табына торган нәрсәләре (кояш, ай, ташлар, сыннар, агачлар һ.б.ш.).

Нәрсәне булса да: «бу яхшы нәрсәдер»,– дип бәяләү асылда ике мәгънәгә кайтып кала: 1) ул нәрсәнең азык буларак яки дәва буларак файдалы булуы, 2) һичбер яктан да зарарлы булмавы.

Бу ике мәгънәгә туры килгән һәрбер азык, ашамлык, эчемлек, әлбәттә, яхшы була. Коръәндә хәлал кыйлынган таййибатне билгеләүдә иң дөрес юл, иң дөрес үлчәү будыр.

Коръәндә азык-төлек буларак искә алына торган таййибатне яки хәбис нәрсәләрне билгеләгәндә безнең фәкыйһларның[1] күбесе гарәпләрнең табигатьләрен, теләкләрен, зәвыкларын нигез итеп алганнар. Таййибат, *хәбаъис*[2], дигән сүзләр гарәп сүзләре булганга күрә, аларның мәгънәләрен ачыклау өчен гарәпләрнең зәвыкларына иярү, әйтерсең лә, мәҗбүри. Ягъни, гарәп зәвыгы теге яки бу ризыкны хуш күрсә, ул ашамлык яхшы дип санала; әгәр дә гарәпләрнең табигате ул ашамлыктан нәфрәт итсә, ул нәрсә начар дип санала. Фәкыйһларның яхшы ризык белән начар ризыкка биргән билгеләмәләре әнә шуңа кайтып кала.

Дөрес, *таййибат*, *хәбаъис* сүзләре – гарәп сүзләре. Гарәп сүзләренең мәгънәләре гарәпләрнең гореф-гадәте белән, гарәпләрнең аңлаулары белән тәгайен ителә[3]. Ләкин, аңлашылган мәгънәләрнең нечкәлекләренә, аларга салынган эчтәлеккә төшенгәндә бары тик гарәпләрнең зәвыклары, теләкләре хакимлек итәргә, өстенлек итәргә тиеш түгел булса кирәк. Бөтен кешелек дөньясы өчен шәригать буларак, ягъни, яшәеш кануны буларак иңдерелгән Коръән кәримнең хөкемнәренә *бәдәвият*[4] дөньясында гомер итә торган гарәпләрнең зәвыклары гына нигез була алмый.

Таййибатнең, хәбаъиснең ни икәнлеген аңлатканда бер үлчәү кирәк булса, андый үлчәү вазифасын таза-сау кешенең сәламәт табигате башкара ала. Кешенең бәдәненә я ризык, я дәва булып,

---

[1] фәкыйһ – шәригать буенча белгеч булган дин галиме, ягъни фикъһы белгече.

[2] хәбаъис (берлектә: хәбис) – начарлыклар, начар булган нәрсәләр.

[3] тәгайен ителә – ачыклана, аңлашыла.

[4] бәдәвият – чүлдә яши торган гарәп кавемнәренең яшәү рәвеше, көнкүрешләре, күчмә тормыш культурасы.

нинди дә булса зарары булмаса, андый ашамлык яхшы була; шуңа күрә, андый ризык, әлбәттә, хәлал була. Әгәр дә ашамлык кешенең я бәдәненә, я диненә зарар бирә алса, андый ашамлык хәбис, ягъни начар була, шуңа күрә, ул, әлбәттә, хәрам була.

Дөрес, җир йөзендә булган барлык нәрсәләр: җирдән чыккан файдалы казылмалар, үсемлекләр, хайванннар – болар барысы да кешенең алардан файдалануы өчен барлыкка китерелгәннәр. Бар булган бөтен нәрсә Аллаһның ихсаны[1] белән кешеләргә кулланулары, файдаланулары өчен тапшырылган кебек. Һәр кеше һәр нәрсәдән, әлбәттә, файдалана ала. Һәр нәрсәдә асыл сыйфат – аны ирекле сурәттә куллану, аннан файда күрүдер; һәр нәрсәнең асылы аның хәлал булуыннан гыйбарәт.

Чыннан да, бу нигез – исламияттә иң хөрмәтле, иң нык бер нигездер. Әлеге нигез җир йөзендә кешелек дөньясының хәлифә[2] булуы өчен чынбарлыкка ашырылган бер зарури нәрсәдер. Болай булу Коръәннең күпсанлы айәтләре белән дә расланган бер хакыйкатьдер.

(هُوَ الَّذِي خَلَقَ لَكُم مَّا فِي الأَرْضِ جَمِيعاً) (әл-Бәкара сүрәсе, 29) [3].

Әлеге хак нигезне игътибар үзәгенә алып, безнең фәкыйһлар: «*Шәригъның исерткеч-хәмер һәм үләксә кебек искәрмә иткән нәрсәләреннән кала ашарга яраклы нәрсәләрне бергә җыюының максаты – аларның ашалуын хәлал итүдер, чөнки алар Аллаһ колларының файдаланулары өчен яратылган*»,– дигәннәр.

Мин дә бу нигезне, хакыйкать буларак, әлбәттә, кабул итәм. Чынлап та, бар булган бөтен нәрсәләр кешенең милкедер, инсанның[4] алардан файдалануы өчен халикъ кыйлынгандыр. Кеше һәрнәрсәне дә куллана ала, тота ала, сарыф итә ала; һәрнәрсәдән файдалана ала. Бу йөздән, азык-төлек, тәгам-ашамлыкларның һәрбереннән кеше файдалана. Ләкин, файдалану юллары, куллану рәвешләре бары тик ашау-эчү, тамак туйдыруга кайтып калмый. Мәсәлән, агу да кешенең милкедер; кеше

---

[1] ихсан – мәрхәмәт, игелеклелек.

[2] хәлифә – Аллаһның вәкаләтле вәкиле.

[3] «Ул җир йөзендә булган нәрсәләрнең барысын да сезнең өчен барлыкка китерүчедер» (2:29).

[4] инсан – кеше.

агудан, зәһәрдән файдалана ала. Ләкин, аны ашап, шул рәвешле үз-үзен үлдерү рәвешендә түгел, бәлки үзенең мәнфәгате, хаҗәте өчен кулланып, шул агуның файдасын күрә.

Табигатьдә файдасыз булган, артык, кирәксез булган һичнәрсә дә юк. Илаһи хикмәт куллары табигатьне иҗат итеп барлыкка китергәндә, һичбер вакыт хаталанмаганнар. Илаһилык үзе карар кыйлган чараларында һичбер вакыт уен-шаяру өчен эш итмәгән. Шуңа күрә, җир йөзендә булган нәрсәләрнең һәрберендә, әлбәттә, нинди дә булса бер файда, нинди дә булса бер хикмәт бар.

Һәрбер нәрсә, үзенә хас булган файдасы өчен кулланылу шарты белән, кешенең куллануы өчен халык кыйлынган[1]. Һәрбер нәрсә, үзенә хас булган файдасы өчен кулланылу шарты белән, мөбахтыр[2]. Шул ук агу мөбахтыр, кеше агуны файдалана ала, ләкин аны ашау юлы белән түгел, чөнки агу ашау файда бирми, киресенчә, кешенең гомерен өзә.

Әмма, һәрнәрсәдән, һәр ашамлыктан файда алуның хәлал булуы гомуми сурәттә ашамлыкларның хәлаллегенә нигез була алмый. Чөнки куллану бары тик ашау-эчү хосуслары белән чикләнелмәгән. Шуңа күрә, фәкыйһларның: «*Шәригъның исерткеч-хәмер һәм үләксә кебек искәрмә иткән нәрсәләреннән кала ашарга яраклы нәрсәләрне бергә җыюының максаты – аларның ашалуын хәлал итүдер*»,– дигән сүзләре дөрес булмый.

Дөрес, һәрнәрсәдә асыл – ирекле рәвештә гамәл кыйлуның рөхсәт ителгән булуыдыр. Ягъни, файдасына күрә куллану, мәнфәгатенә күрә файдалану һәрнәрсәгә карата рөхсәт ителә. Ләкин, файдалануның рөхсәт ителгән булуы ашау-эчүнең дә рөхсәт ителгән булуын белдерми. Ашау-эчүнең ясакланган булуы файдалануның ясакланган булуына да дәлил булмый. Мәсәлән: зәһәр-агу ашау хәрамдер, ләкин аңа хас булган файдаларын куллану хәлалдер. Лашә[3] ашау хәрамдер, ләкин ашаудан башка хосусларда аның бер файдасы булса, аннан

---

[1] халык кыйлынган – барлыкка китерелгән, яратылган.

[2] мөбах – шәригать күзлегеннән тыелмаган гамәл яки начар булмаган нәрсә. Игелекле ният белән кылынган мөбах гамәл саваптан китә, яман гамәл – гөнаһтан.

[3] лашә – үләксә.

файдалану, әлбәттә, рөхсәт ителә. Ыспирт эчмәк хәрамдер, ләкин ыспирт пакьтер, аның файдалы якларын куллану рөхсәт ителә. Ул гытрияттә[1], сәнәгать-җитештерүдә кулланыла ала.

Гамәл кыйлу ирегe белән, ягъни куллануның хәлаллеге белән ашау-эчү хәлаллеге арасында тыгыз бәйләнеш юк. Һәрбер хәлалнең пакь булуы зарури булса да, һәрбер хәрамнең нәҗес[2] булуы шарт түгел. Бу мәсьәлә «Ифадәт әл-кирам» исемле китапның[3] 3–4 нче сәхифәләрендә урын алган 14 нче юлда нәҗасәтнең[4], тәһарәтнең хөкемнәре белән бәрабәр[5] аңлатылган.

Ашалуы-эчелүе хәрам булган һәрбер нәрсәнең нәҗеслеге хакында, һәм дә ашалуы-эчелүе хәрам булган нәрсәләрне башкача куллануның хүрмәте[6] мәсьәләсендә мин фәкыйһларга каршы чыгам. Аларның: «*Һәр ризыкта аны ашауның хәлал булуы асылдыр*»,– дигән сүзләренә дә мин кушыла алмыйм.

Шәригать күзлегеннән караганда нинди дә булса азык-төлекнең хәлал булуы өчен өч рөкен[7], өч асыл сыйфат бар:

1) Пакьлек. Әгәр ризык сәламәт табигатьле берәүне нәфрәтләндерә алырлык дәрәҗәдә шакшы, начар, бозык булса, андый ашамлык хәлал булмый.

2) Файда, ягъни ашамлыкның кеше бәдәненә я азык, я дәва кебек файдага ия булуы. Тәгамнең мөһим рөкене шулдыр. Инсанның ризыкка ихтыяҗы да бары тик әлеге үзенчәлеккә кайтып кала.

3) Зыянлы булмау, ягъни ашамлыкның кеше бәдәненә дә, диненә дә зарар бирмәве.

Шушы өч рөкенгә туры килгән ашамлыклар тайийбат җөмләсеннән булып, хәлал булалар.

[1] гытирият – хушбуй, ислемай җитештерү, парфюмерия.

[2] нәҗес – нинди дә булса шакшы нәрсә.

[3] «Ифадәт әл-кирам» – Мисырда яшәгән шәйхелислам, «мөэминнәрнең хәдистәге әмире» дәрәҗәсенә лаек булган Ибне Хаҗәр әл-Әскаланиның (м. 1342–1448) әсәре. Муса Бигиев тарафыннан 1909 елда Казанда нәшер ителгән.

[4] нәҗасәт (берлектә: нәҗес) – шакшы нәрсәләр.

[5] бәрабәр – бергә, бергәләп, бергәлектә.

[6] хүрмәт – ясакланган булу, тыелган булу, хәрам булган нәрсә.

[7] рөкен – терәк, нәрсәнең дә булса терәге булып торган багана.

Кешенең вөҗүденә[1] азык була алган мәгъдәният[2], үсемлекләр – боларның һәрбере хәлалдер.

(وَهُوَ الَّذِي أَنشَأَ جَنَّاتٍ مَّعْرُوشَاتٍ وَغَيْرَ مَعْرُوشَاتٍ وَالنَّخْلَ وَالزَّرْعَ مُخْتَلِفًا أُكُلُهُ وَالزَّيْتُونَ وَالرُّمَّانَ مُتَشَابِهًا وَغَيْرَ مُتَشَابِهٍ كُلُواْ مِن ثَمَرِهِ إِذَا أَثْمَرَ وَآتُواْ حَقَّهُ يَوْمَ حَصَادِهِ وَلاَ تُسْرِفُواْ إِنَّهُ لاَ يُحِبُّ الْمُسْرِفِينَ) (әл-Әнгам сүрәсе, 141) [3].

(يُنبِتُ لَكُم بِهِ الزَّرْعَ وَالزَّيْتُونَ وَالنَّخِيلَ وَالأَعْنَابَ وَمِن كُلِّ الثَّمَرَاتِ) (сүрәт ән-Нәхел, 11) [4].

(وَمَا ذَرَأَ لَكُمْ فِي الأَرْضِ مُخْتَلِفًا أَلْوَانُهُ) (ән-Нәхел, 13) [5].

(فَأَنشَأْنَا لَكُم بِهِ جَنَّاتٍ مِّن نَّخِيلٍ وَأَعْنَابٍ لَّكُمْ فِيهَا فَوَاكِهُ كَثِيرَةٌ وَمِنْهَا تَأْكُلُونَ) (әл-Мөэминүн сүрәсе, 19) [6].

(هُوَ الَّذِي خَلَقَ لَكُم مَّا فِي الأَرْضِ جَمِيعاً) (әл-Бәкара сүрәсе, 29) [7].

(يَا أَيُّهَا النَّاسُ كُلُواْ مِمَّا فِي الأَرْضِ حَلاَلاً طَيِّباً) (әл-Бәкара сүрәсе, 168) [8].

Бу мәгънәдә иңдерелгән айәт кәримәләрнең ачык дәляләтләре[9] белән мәгъдәниятнең, үсемлекләрнең хәлаллекләре, ашау өчен яраклы булулары расланган. Инсанның бәдәненә зарар бирә ала торган мәгъдәният һәм үсемлекләр, әлбәттә, ни ашамлык була алмый, ни яхшы нәрсә, ягъни тай-

---

[1] вөҗүд (барлык, тән, гәүдә) – биредә организм мәгънәсендә аңлау дөрес булса кирәк.

[2] мәгъдәният – җирдән алынган матдәләр, минераллар. Андыйлардан, мәсәлән, тозны атап була.

[3] «Терәкле һәм терәксез җимеш бакчаларын, төрле тәмнәргә ия булган хөрмә агачларын һәм игеннәрне, бер-берсенә охшаган һәм үзара аермаларга ия булган зәйтүн вә нар җимешләрен барлыкка китерүче Улдыр. Шул җимешләр өлгергәч аларны ашагыз» (6:141).

[4] «(Ул) сезнең өчен игеннәрне, зәйтүннәрне, хөрмә агачларын, йөземнәр вә җиләк-җимешләрнең һәммәсен үстереп тора» (16:11).

[5] «(Ул) сезгә дип җир йөзендә төрле төстәге (ризыклар) таратты» (16:13).

[6] «(күктән яуган яңгыр) белән Без сезнең өчен хөрмә белән йөзем бакчалары үстердек. Аларда сезнең өчен күп җимешләр бар, һәм дә сез шуларны ашыйсыз» (23:19).

[7] «Ул җир йөзендә булган нәрсәләрнең барысын да сезнең өчен барлыкка китерүчедер» (2:29).

[8] «Әй, кешеләр! Җир йөзендәге нәрсәләрнең хәлал һәм яхшы булганнары белән тукланыгыз» (2:168).

[9] дәляләт – дәлиллек итү, дәлил булу.

йибат, була алмый. Шуңа күрә, андый нәрсәләр айәтләрнең гомуми мәгънәсенә дә кермиләр.

Коръәндә кешеләргә азык буларак, тәгам буларак хәлал кыйлынган хайваннардан бары тик әнгам[1] җенесе искә алына.

(أُحِلَّتْ لَكُم بَهِيمَةُ الأَنْعَامِ) (әл-Маъидә, 1) [2].

(وَمِنَ الأَنْعَامِ حَمُولَةً وَفَرْشًا كُلُواْ مِمَّا رَزَقَكُمُ اللهُ وَلاَ تَتَّبِعُواْ خُطُوَاتِ الشَّيْطَانِ إِنَّهُ لَكُمْ عَدُوٌّ مُّبِينٌ) (әл-Әнгам сүрәсе, 142) [3].

(وَالأَنْعَامَ خَلَقَهَا لَكُمْ فِيهَا دِفْءٌ وَمَنَافِعُ وَمِنْهَا تَأْكُلُونَ) (ән-Нәхел, 5) [4].

(وَإِنَّ لَكُمْ فِي الْأَنْعَامِ لَعِبْرَةً نُّسقِيكُم مِّمَّا فِي بُطُونِهَا وَلَكُمْ فِيهَا مَنَافِعُ كَثِيرَةٌ وَمِنْهَا تَأْكُلُونَ) (әл-Мөэминүн, 21) [5].

(أَوَلَمْ يَرَوْا أَنَّا خَلَقْنَا لَهُمْ مِمَّا عَمِلَتْ أَيْدِينَا أَنْعَامًا فَهُمْ لَهَا مَالِكُونَ وَذَلَّلْنَاهَا لَهُمْ فَمِنْهَا رَكُوبُهُمْ وَمِنْهَا يَأْكُلُونَ) (Йасин, 71–72) [6].

(أَللهُ الَّذِي جَعَلَ لَكُمُ الْأَنْعَامَ لِتَرْكَبُوا مِنْهَا وَمِنْهَا تَأْكُلُونَ) (әл-Мөэмин, 79) [7].

Кеше өчен итләре ашарга яраклы, хәлал булган хайваннар Коръәндә байтак сүрәләрдә, күпсанлы айәт кәримәләрдә искә алынган булсалар да, һәр айәттә сүз, нидәндер, бары тик йорт хайваннары турында, терлек турында бара.

Гарәп телендә *әнгам* [мал-туар] төшенчәсе үз эченә *ибил* [дөя], *бәкар* [эре мөгезле терлек], *ганәм* [куй-сарык] җенесллә-

[1] әнгам (берлек санда – нәгам) – терлек, мал-туар. Нигъмәт сүзе белән бар тамырдан ясалган сүз.

[2] «Сезнең өчен мал-туар хәлал ителде» (5:1).

[3] «Мал-туар арасында йөк ташый торганнары һәм йоннарыннан түшәк ясала торганнары бар. Аллаһның сезгә ризык буларак биргәне белән тукланыгыз» (6:142).

[4] «Мал-туар дигәндә, Ул аны сезнең өчен барлыкка китерде. Ул мал-туардан җылыну һәм башка төрле файдалар бар, һәм сез шулар белән тукланасыз да» (16:5).

[5] «Сезнең өчен терлектәдер гыйбрәт: сезне аларның эчендәгеләр белән сугарабыз һәм сезнең өчен анда күп файда бар. Һәм сез шулар белән тукланасыз да» (23:21).

[6] «Безнең кулларыбыз эшләгәннән алар өчен терлек барлыкка китергәнебезне һәм үзләренең шул терлеккә ия булуларын күрмиләр микәнни? Аны (терлекне) аларга буйсындырдык. Шулар арасында алар атланып йөри торганнары бар. Һәм шулар белән тукланалар да» (36:71–72).

[7] «Аллаһ кайберләренә атланып йөрүегез өчен сезгә терлек җитештерде. Һәм сез шулар белән тукланасыз да» (40:79).

рен ала. Коръәннең «сәманияту әзваҗин»[1] турындагы айәтләрендә мал-туар төшенчәсе тәфсилле сурәттә аңлатылганда, бары тик сарыклар, кәҗәләр, дөяләр, эре мөгезле төрлек искә алынган. «Маъидә», «Хаҗ» сүрәләрендә урын алган күпсанлы айәтләрдә һәдьйиләр[2], корбаннар искә алынганда, һаман әнгам генә телгә алына.

Шуңа күрә, фикъһы мәзһәбләренең[3] күпчелеге карашында ите хәлал булган хайваннарның төрләре чикле.

Ат ите хакында әһле гыйлем[4] арасында зур каршылыклар бар. Күпчелекнең фикеренчә ат ите, әлбәттә, хәлалдер. Әмма сәдат мәликия[5] карашына күрә ат ите катгый хәрамдер.

Халид бин әл-Вәлид[6] хәзрәтләре риваять итмеш ки: «*Хәйбар көнендә пәйгамбәр, саллә Аллаһу галәйһи вә сәлләмә, ат итен хәрам кыйлды*».

Бу хәдис ышанычлы, *сабит* [нык] булса иде, ат итенең хәрам булуына дәлил була алыр да иде, бәлки. Ләкин хәдис нык кына түгел, хәтта мөнкәр, ягъни кире кагыла торган хәдистер. Нигәме? Чөнки Халид ибн әл-Вәлиднең исламны кабул итүе Хәйбар газәсеннән[7] соң иде. Бу хәдис, әйтик, сабит та булсын

[1] «сәманияту әзваҗ» – сигез пар җан иясе.

[2] һәдьйи – корбан буларак чалыначак терлек.

[3] фикъһы мәзһәбләре – бу төшенчәнең тар, әмма иң киң таралган мәгънәсе исламда шәригать кануннарын булдыруда һәм тормышка ашыруда кайбер үзенчәлекләргә һәм аермаларга ия булган фикригамәли юнәлешләрне белдерә. Мәсәлән, биредә хәнәфи, шәфигый, мәлики һәм хәнбәли фикъһы мәзһәбләре күздә тотыла.

[4] әһле гыйлем – дини белемгә ия булган галимнәр, шәригать белгечләре.

[5] сәдат мәликия – имам Мәлик (Әбү Габдуллаһ Мәлик ибнде Әнәс әл-Әсбахый, м. 713–795) хәзрәтләренең исемен йөртүче фикъһы мәзһәбенең атаклы вәкилләре.

[6] Халид ибн әл-Вәлид (м. 592–642/643) – Мөхәммәт пәйгамбәрнең (ﷺ) сәхабәсе. Ислам динен кабул иткәнче Өхед сугышы вакытында (м. 625 ел.) мөселманнарга каршы якта сугышып, аларга зур зыян китергән була.

[7] газә (күплек санда: газават) – яу чабу, сугыш сәфәренә чыгу. Әлеге сүздән Мөхәммәт пәйгамбәр (ﷺ) оештырган һәм катнашкан яуларны белдергән әл-Мәгази (Пәйгамбәр яулары) дигән тарихи тө-

ди, тик бу очракта да ул ат итенең хүрмәтенә, ягъни тыелган булуына дәлил була алмый, чөнки аның җиһад көннәрендә атларга ихтыяҗның көчле булуы аркасында гына тыелган булуы яхшы аңлашыла.

Ат итен тәхрим иткән әһле гыйлем үзләренең бу карарларын: «*Ат өч нәрсә өчен: кеше өчен ул саклаучы, кеше өчен ул әҗер һәм кеше өчен ул җаваплылык*»,– дип яңгыраган катгый сөннәт, ягъни хәдис белән дә дәлилләгәннәр. Әгәр дә атларның итләре хәлал булса иде, Шәригъ хәким[1]: «*Ат дүрт нәрсә өчен: кеше өчен ул саклаучы, кеше өчен ул әҗер һәм кеше өчен ул җаваплылык, һәм кеше өчен ул азык*»,– дигән булыр иде, имеш.

Атларның итләрен тәхрим иткән әһле гыйлем үзләренең шул хөкемнәрен (وَالْخَيْلَ وَالْبِغَالَ وَالْحَمِيرَ لِتَرْكَبُوهَا وَزِينَةً وَيَخْلُقُ مَا لاَ تَعْلَمُونَ)[2] дигән айәт кәримә белән дә дәлилләгәннәр. Аларның фикеренчә, ат ите әгәр хәлал булса иде, айәттә атларга хас булган мәнфәгатьләр, ягъни кеше өчен булган файдалары бәян кыйлынганда, итләренең хәлал булуы да искә алыныр иде. Ә биредә исә атка атланып йөрү нигъмәте искә алынган; атның зиннәт булуы зикер кыйлынган[3], ләкин итенең хәлаллеге телгә алынмаган, имеш.

Бу рәвешле дәлилләү, шөбһә юк, матур һәм төгәл дәлилләүдер. Ләкин аның дәлиллеге катгый түгел. Чөнки бәгъзы мәнфәгатьләр, ягъни файдалар турында дәшми калу ул мәнфәгатьләрнең чикләнелгән булуына дәлил булмый. Юкса, атларга йөк йөкләү мәнфәгате дә хәрам булырга тиеш булыр иде. Югарыда китерелгән айәт кәримәдә атлар белән бәйле булган гомуми файдаларның иң зурлары гына искә алынган. Итнең хәлал булуы әлеге өч төр хайван арасында: ягъни атлар, качырлар[4] һәм ишәкләр өчен уртак булган файда түгел, шуңа күрә ул искә алынмаган да булса кирәк.

---

шенчә ясалган.

[1] Шәригъ хәким – хикмәт иясе булган шәригатьче, ягъни Мөхәммәт пәйгамбәр (ﷺ).

[2] «һәм (барлыкка китерде) атларны, качырларны, ишәкләрне аларга атланып йөрүегез өчен һәм зиннәт буларак» (16:8).

[3] зикер кыйлынган – искә алынган.

[4] качыр – бия белән ишәктән туган кушылдык.

Коръән кәримдә атларның хәлаллеге хакында сүз булмаса да, атларның хәлаллеге әсхаб кирамның[1] иҗмагы[2] белән, катгый хәдисләрнең дәлилләре белән расланган.

«*Җабирдән: «Чынлыкта, рәсүлүллаһ, саллә Аллаһу галәйһи вә сәлләмә, йорт ишәге итләрен ясаклады, ә ат итләрен рөхсәт итте*», муттафак галәйһи[3].

«*Әбү Бәкернең кызы Әсмадән: «Без расүлүллаһ саллә Аллаһу галәйһи вә сәлләмә дәверендә Мәдинәдә яшәгән чагыбызда бер ат чалган идек. Аны без һәм Әһле бәйт[4] ашадык*».

«*Ибне Әбү Шәйба ике шәех[5] куйган шартны үтәп ышанычлы сәнәд белән Гатадан тапшырды ки, шул Гатаның Ибне Җөрәйеҗгә: «Синең сәләф бабаларың аны ашаудан туктамадылар»,– дип әйткәнен. Ибне Җөрәйеҗ Гатадан: «Рәсүлүллаһның сәхабәләреме?»,– дип сораган. Гата: «Әйе!»,– дип җавап биргән*».

Әлеге катгый хәбәрләрнең ачыктан-ачык бәяннарына күрә, ат ите, әлбәттә, хәлалдер.

Йорт ишәге, хәдисләрнең катгый хәбәрләренә күрә, тәхрим кыйлынган. Ләкин кыргый ишәк хәлалдер. Сәгыб бин Җәссамә, Гамир бин Сәлма, Әбү Катада кебек сәхабәләрнең озын кыйссалары бөтен хәдис китапларында тәфсилле сурәттә китерелеп, кыргый ишәкнең хәлаллеге катгый сурәттә расланган. Коръән кәримнең (يَا أَيُّهَا الَّذِينَ آمَنُواْ لاَ تَقْتُلُواْ الصَّيْدَ

---

[1] әсхаб кирам – Мөхәммәт пәйгамбәрнең (ﷺ) сәхабәләре, ягъни пәйгамбәр исән чакта ислам динен кабул итеп, аңа ияргән кешеләр, беренче мөселманнар.

[2] иҗмагъ – фикъһы гыйлемендә галимнәрнең уртак фикергә килүләре нигезендә шәригать хөкеме чыгару.

[3] мөттәфак галәйһи (килешүле) – «килешүле» хәдисләр дип Бохари белән Мөслим төзегән мәшһүр хәдис җыентыкларының икесендә дә очрый торган хәдисләр атала. Әлеге хәдис Бохариның «Әл-Җәмигъ әс – Сахыйх»ында – 4219-нчы, ә Мөслимнең «Сахыйх»ында 1941 нче номер белән теркәлгән.

[4] Әһле бәйт – Мөхәммәт пәйгамбәр (ﷺ) гаиләсенең вәкилләре.

[5] ике шәех куйган шарт – имам Бохари белән имам Мөслимнең хәдис иснадының дөреслеген ачыклау өчен куйган таләпләре күздә тотыла.

(وَأَنتُمْ حُرُمٌ أُحِلَّ لَكُمْ صَيْدُ الْبَحْرِ وَطَعَامُهُ مَتَاعًا لَّكُمْ وَلِلسَّيَّارَةِ وَحُرِّمَ عَلَيْكُمْ)[3] һәм дә (صَيْدُ الْبَرِّ مَا دُمْتُمْ حُرُمًا وَاتَّقُواْ اللّهَ الَّذِيَ إِلَيْهِ تُحْشَرُونَ)[1] дигән айәт кәримәләренә кыргый ишәк, шөбһәсез, керә, чөнки ул заманда ауның иң еш очрый торган төре ул – кыргый ишәкләрне аулау иде.

Куян, таушан[2] ите дә хәлалдер.

«*Әнәснең: «Бервакыт Мәрре-з-Заһранда бездән куркып бер куян чыгып чапты. Халык аны куа-куа арып бетте, әмма мин аны тотып алдым да Әбү Талхага илтеп тоттырдым. Ул куянны чалды да, аның ике ботын рәсүлүллаһ, салләАллаһу галәһйи вә сәлләмәгә, илтеп бирде, һәм ул күчтәнәчне кабул итеп алды»,– дип әйткәне тапшырыла*», мөттафак галәйһи.

Керпе ите хакында каршылыклы фикерләр бар:

«*Гайсә бине Намилә әл-Физаринең әйтүенчә, аның әтисе болай дигән булган: «Мин Ибне Гомәр янында булганда, ул керпе итен ашау турында сорады да Җәллә сәнаъүһүнең*[3]*:* (قُل لَّا أَجِدُ فِي مَا أُوْحِيَ إِلَيَّ مُحَرَّمًا)[4] *– дигән айәтен тилавәт кыйлды* [укып бирде]. *Шунда моны ишетеп алган бер карт әйтте ки: «Әбү Һөрәйрәнең бу турыда пәйгамбәрдән сораганын ишеттем һәм пәйгамбәр: «Шакшының шакшысы»,– дигән иде». Ибне Гомәр: «Әгәр пәйгамбәр моны әйткән булса, димәк ул нәкъ шулай дигән дә инде»,– диде*».

---

[1] «Ихрам хәлендә килеш үзегезнең вә юлчыларның рәхәте өчен диңгездә ауга чыгу һәм андагы ашамлыклар сезгә хәлал ителде, ә җирдә ауга чыгу хәрам ителде» (5:96).

[2] таушан – йорт куяны (кролик).

[3] Җәллә сәнаъүһү (бөек булсын Аның мактaлуы) – Аллаһ Тәгаләне олылау сүзләре.

[4] «Әйт: «Миңа индерелгән вәхийдә ашаучы өчен аның ашый торган тәгамнары арасында мин үләксә, агызып алынган кан, шакшылыкның үзе булган дуңгыз ите һәм Аллаһыдан башка бер нәрсәгә атап чалынган нәрсәләрдән башка хәрам булган нәрсәләр тапмыйм» дигән айәт күздә тотыла (6:145).

Боларны Әхмәд[1] белән Әбү Давыт[2] риваять кыйлдылар. Ошбу хәдис сабит булса да, булмаса да, керпе итенең хәрам булуы өстенрәк, чөнки шакшы нәрсәләрне ясаклау Коръән кәримдә әйтелгәннәр белән расланган.

«*Ибне Габбастан: «Пәйгамбәр, саллә Аллаһу галәйһи вә сәлләмә, казык тешләре булган хайваннарны һәм тырнаклары булган кошларны ашаудан тыйды»*[3]. Әл-Җумага риваять итте.

Бу мәгънәдә Әбү Һөрайрәдән, Әбү Сәгъләбтән, Гали (Аллаһ аңардан разый булсын) хәзрәтләреннән күпсанлы хәдисләр риваят кыйлынган. Теше белән, йә тырнагы белән көн күрә торган ерткыч хайваннарның, кошларның итләре хәрам кыйлынмыштыр.

«*Җабирдән хәбәр ителгәнгә күрә, пәйгамбәр мәче итен ашауны һәм мәче сатудан казанылган керем исәбенә сатып алынганнарны ашауны тыйды*». Хәдисне Әбү Давыт, Ибн Маҗә һәм Әт-Тирмизи риваять кыйлганнар.

«*Гаъишәдән: «Рәсүлүллаһ, саллә Аллаһу галәйһи вә сәлләмә: «Биш төрле начар нәрсәне хәрәмдә (Мәккәдә) һәм хәрәмнең тышында үтерергә ярый, ул да булса: елан, чуар козгын, тычкан, усал эт, чаян»,– диде*». Ошбу хәдисне Әхмәд, Мөслим, Ибн Маҗә һәм Әт-Тирмизи хәзрәтләре риваять иткәннәр.

«*Өмме Шәриктән хәбәр ителгәнгә күрә, пәйгамбәр кәлтә еланнарны[4] үтерергә кушкан*» (мөттәфак галәйһи).

«*Габдеррахман бине Госман әл-Каршинең хәбәр итүенә күрә, бер табип пәйгамбәрдән дару әзерләүдә бака кулланылуының хөкеме турында сораган. Пәйгамбәр аны үтерүдән тыйган*». Бу хәдисне Әхмәд белән Әл-Хаким риваять иткәннәр.

[1] Әхмәд – хәнбәли мәзһәбенә нигез салган Әхмәд ибне Хәнбәл (м. 780–855).

[2] Әбү Давыт (Сөләйман ибн әл-Әшгас әс-Сиҗистани, м. 817–889) – хәдис белгече, «Сөнән Әбү Давыт» исемле хәдисләр җыентыгын төзүче.

[3] Әлеге хәдис имам Мөслимнең «Сахыйх»ында 1934 нче номер белән теркәлгән.

[4] Хәдистә сүз кәлтә еланнарның (الوزغ), дип аталган, ягъни геккон (Gekkonidae) исемле бер генә төре турында бара.

Бу мәгънәдә килгән хәдисләрнең ачык гыйбарәләренә күрә, ерткыч кошларның, ерткыч хайваннарның, елан, тычкан кебек хәшәрәтләрнең итләре хәрамдер. Шәфигый, хәнбәли, хәнәфи мәзһәбләре бу мәсьәләдә иттифакъ[1] итмешләр.

Сәдат мәликия кашында ерткыч кошларның, ерткыч хайваннарның, керпе, тычкан, елан кебек хәшәрәтләрнең итләре хәлалдер. Бары тик дүрт хайванның: дуңгызның, атның, ишәкнең, качырның итләре хәрамдер.

Сәдат мәликияләрнең мәзһәбенә мин, әлбәттә, ихтирам күзе белән карыйм. Ләкин, югарыда китерелгән шәригать чыганакларының һәм дә (وَيُحَرِّمُ عَلَيْهِمُ الْخَبَآئِثَ)[2] дигән айәт кәримәсенең гомуми мәгънәсе өч мәзһәбнең карашларына өстенлек бирә. Чөнки хәшәрәт хәтле хәшәрәт тә хәбаъис булмаса, ул чакта хәбаъис ни була соң?

«*Ибне Гомәрнең ошбу сүзләре хәбәр ителә: «Пәйгамбәр, салләллаһу галәйһи вә сәлләмә, үләксә вә нәҗес ашый торган хайваннарны (әл-җәллаләә) да, аларның сөтен дә хәрам кыйлды*». Хәдисне Әл-Җөмәга риваять иткән[3].

*Җәллаләә* – үләксә вә нәҗес ашый торган хайванларга, кошларга карата кулланыла торган гомуми атамадыр.

Сәдат шафигыя, сәдат хәнәфия, сәдат хәнбәлия[4] бу хәдиснең тышкы мәгънәсе белән гамәл кыйлып, үләксә, нәҗес ашый торган хайван һәм кошларны тәхрим иттеләр.

Кош яки хайван, асылда, җәллаләә булмыйча торып, еш кына үләксә, нәҗасәт ашый торган булса, сәдат хәнәфия кашында андый хайваннарның итләре, сөтләре вакытлы сурәттә мәкруһ[5] була. Беркач көн бикләнеп тотылганнан соң пакьләнер.

---

[1] иттифакъ итмешләр – бердәм булганнар, бер караштa булганнар.

[2] «вә алар өчен шакшы нәрсәләрне хәрам итә» (7:157).

[3] хәдис Әбү Давытның «Сөнән»ендә 3719 нчы номер белән, Әт-Тирмизинең «Җәмигъ»ында 1825 нче номер белән теркәлгән.

[4] сәдат шафигыя, сәдат хәнәфия, сәдат хәнбәлия – имам Әбү Габдуллаһ Мөхәммәд ибне Идрис әш-Шәфигый (м. 767–820), имам Әхмәд ибне Хәнбәл (м. 780–855), имам Әбү Хәнифә (м. 699–767) исемнәрен йөртүче фикъһы мәзһәбләренең танылган галимнәре.

[5] мәкруһ – эшләнүе хупланмаган гамәл.

Итләре ашау өчен хәрам булган хайваннар хакында югарыда китерелгән хәдисләр диккать белән укылсалар, кешенең аш-суы хосусларында Шәригъ хәкимнең күрсәтмәләре билгеле була.

Ризык кешенең бөтен вөҗүденә һәм әхлагына, әлбәттә, тәэсир итә. Ризык кешенең тән вә әхлак сәламәтлегенә дә, әлбәттә, сәбәп була ала. Ашала торган азык-төлеккә хас булган сыйфат вә хасиятләр эзлекле һәм даими сурәттә кешенең бәдәненә дә, әхлагына да күчәләр.

Шуңа күрә, кешенең әдәп-әхлагына, бәхет-сәгадәтенә нисбәтән адәм баласына карата лаек булмаган начар табигатькә ия булган хайваннарның итләре Шәригъ хәкимнең теге яки бу шәригать канунын булдырганда кешеләрне кайгыртып, аларның игелеге турында борчылып эш итүе аркасында хәрам ителгән булса кирәк.

Табигатьләре начар итеп яратылган хайваннар берничә төрледер:

1) Ерткыч хайваннар. Ерткыч хайваннарга ерткычлык, йөрәк катылыгы, мәрхәмәтсезлек кебек яман табигать хас. Ерткыч хайваннарның итләре кешеләрне әнә шундый начар әхлактан саклау чарасы буларак тәхрим кыйлынган булса кирәк.

2) Кешеләрне газаплануга дучар итә ала торган хайваннар. Мәсәлән, елан кебек, чаян кебек, ягъни кешеләрне чага торганнар. Карга кебекләре исә, бакчаларда җитешеп яткан җиләк-җимешләргә, игеннәргә зыян китерә.

3) Куркаклык, качкынлык, түбәнлек табигатенә ия булган хайваннар: чокырларда, өннәрдә гомер итә торган тычкан-күсе кебек, төрле хәшәрәтләр кебек.

4) Үләксә ашап, нәҗасәт белән тукланып гомер итә торган хайваннар.

5) Ахмаклыкка, хурлыкка дучар ителгән хайван, мәсәлән, ишәк кебек.

Гомумән алганда, бу хайваннарның табигатьләре кешенең табигатенә һәрьяклап туры килмәгәнгә күрә, аларның итләрен ашау тыйб[1] хөкеме белән дә тыелган. Кешенең бөтен барлыгы,

[1] тыйб (гарәп.: тыйбб) – медицина.

табигате аның ашаган ризыгыннан килә. Кешенең әхлагы да, күбесенчә, ашаган тәгаменнән, алган тәрбиясеннән тора. Хайваннарга хас булган табигый әхлак, табигать канунының хөкеме белән, аның итен ашап тукланган кешеләргә, әлбәттә, күчә.

Бу хакыйкатьне һәм дә Коръән кәримнең айәт кәримәләрен, Шәригъ хәкимнең пәйгамбәр сөннәтләрен нигез буларак файдаланып, сәдат шәфигыя, сәдат хәнбәлия, сәдат хәнәфия итләре хәлал булган хайваннарның төрләрен өч-дүрт төргә сыйдырганнар.

Югарыда инде бәян кыйлынды: Коръән кәримдә итләре хәлал кыйлынмыш хайваннар бары тик йорт хайваннарыдыр. Мондый мал-туар өч төрдән гыйбарәт: 1) дөяләр; 2) эре мөгезле терлек; 3) вак мөгезле терлек.

Дүрт аяклы йорт хайваннарыннан бары тик әлеге өч төре хәлалдер. Атларның хәлаллеге Коръән кәримнең айәт кәримәләре белән расланмаган булса да, ул хәлаллек сәләфнең[1] гамәлләре белән һәм катгый хәдисләрнең дәлилләре белән расланган.

Кыргый хайваннар шушы дүрт төрнең берсенә исемдә яки сыйфатта охшаса, хәлал була, тау кәҗәсе хәлалдер; кыргый сыер хәлалдер, тәвә кошы хәлалдер. Кыргый ишәк тә хәлалдер.

Кош итләренең хәлаллеге хакында Коръән кәримдә ачыктан-ачык сүз юк. Дөрес, «әл-Вакыйга» сүрәсендә, җәннәтләрнең нигъмәтләрен бәян итү арасында, (وَفَاكِهَةٍ مِّمَّا يَتَخَيَّرُونَ وَلَحْمِ طَيْرٍ مِّمَّا يَشْتَهُونَ)[2] дигән айәт кәримә бар. Коръән кәримдә җәннәт нигъмәтләре дөнья нигъмәтләренең тиңдәшләре буларак искә алына. Шуңа күрә, кош итләренең хәлаллеге, әлбәттә, раслана ала.

Кош итләренең хәлаллеге Коръән кәримнән тагын ике юл белән чыгарыла ала:

---

[1] сәләф – турылыклы мөселманнар буларак танылган борынгылар: пәйгамбәрнең сәхәбәләре, алардан гыйлем алган мөселманнар буыны (табигыйннар) һәм табигыйннардан белем алган өченче буын вәкилләре.

[2] «Үзләре сайлап алган җиләк-җимешләр һәм үзләре теләгән кош итләре» (56:20–21).

1) Исламияттән әүвәлдә дә, гасыр-ы рисаләттә[1] дә, кош ите иң киң кулланылган сый булган. Әгәр дә кош ите хәрам булса иде, ул кадәр киң таралган, борынгыдан килгән бу гадәт хакында Коръән кәрим, әлбәттә, дәшми калмас иде. Димәк, бөтен кешелек дөньясының уртак эше һәм әүвәлге шәригатьләрнең хөкеме Коръән кәримнең ризалыгы белән теркәлгән. Нәрсәне дә булса канун рәвешенә китерүнең бу шәкеле иң куәтле, иң нигезле шәкелдер.

2) Мал-туарның ите хәлал кыйлынмыш. Шулай итеп, итләре мал-туар итеннән тагын да пакь, тагын да тәмле булган кошларның хәлаллегә шөбһәгә урын калдырмый торган бәхәссез рәвештә раслана.

Кош итләренең хәлаллеге хакында хәдисләрдә хәбәрләр күп түгел:

1) «*Әбү Муса әл-Әшгаринең: «Пәйгамбәрнең тавык ите ашаганын күрдем»,– дигән сүзләре хәбәр ителә*». Хәдис мөттәфак галәйһидер.

2) «*Пәйгамбәр, саллә Аллаһу галәйһи вә сәлләмә, казык тешләре булган хайваннарны һәм тырнаклары булган кошларны ашаудан тыйды*». Хәдисне Әл-Җөмәга риваять иткән.

Кошларны искә алганда бары тик тырнаклы кошларны ясаклау ул тавык, каз, үрдәк кебек кошларның хәлаллекләрен бәян итүдер. Юкса, хәдиснең файдасы калмас иде.

3) «*Чыпчык яки аннан зуррак берсен кем генә хаксызга үтермәсен, Кыямәт көнендә Аллаһ аны шул кош хакында җавапка тартачак». Шунда: «Аның хакы ни соң?»,– диеп соралды. Әйтте: «Аны чалып ашасын. Башын кисеп өзмәсән һәм алып атмасын*». Бу хәдисне Ибне Гамрудан әд-Даракутни[2] хәзрәтләре тапшырган.

Бу хәдиснең ишарәсе гомуми сурәттә бөтен кошларның хәлаллегенә дәлил була ала, чөнки тәгам әзерләү максаты белән аларны суярга рөхсәт ачыктан-ачык хәбәр ителгән.

---

[1] Гасыр-ы рисаләт – Рәсүлүллаһ Мөхәммәтнең пәйгамбәрлек кылган дәвере (пәйгамбәрлек гасыры).

[2] Әд-Даракутни (м. 918–995) – имам, атаклы хәдисче галим, фәкыйһ, кыйраәт белгече.

Сәдат маликия каршында кошларның бөтен төрләре: йорт кошлары да, киек кошлар да, ерткыч кошлар да, үләксә вә нәҗасәт ашаучылары да – хәлалдер.

Бирегә кадәр һава җанварлары турында сүз йөрттек. Суда яши торган җанварларының хәлаллеге мәсьәләсендә мәзһәб имамнары уртак фикергә килмәгәннәр: сәдат шафигыя, хәнәфия, маликия карашында су хайваннарының һәммәсе, хәтта су кешесе дә[1], су дуңгызы[2] да, үләксәсе дә дә хәлалдер.

Коръән кәримнең айәт кәримәләре бу өч мәзһәбнең дөреслегенә дәляләт итә:

1) (أُحِلَّ لَكُمْ صَيْدُ الْبَحْرِ وَطَعَامُهُ مَتَاعًا لَّكُمْ وَلِلسَّيَّارَةِ) (әл-Маъидә, 96) [3].

Бу айәт кәримәдә «ау» (صَيْدُ) сүзе дә гомуми мәгънәгә ия, «тәгам» (طَعَام) сүзе дә. Сәхабәләрнең аңлатуларына күрә, «сайду әл-бәхри» (صَيْدُ الْبَحْرِ), дигән гыйбарә «диңгездә[4]ауланган хайван», булып чыга, ә «тәгаму-һу» (طَعَامُهُ), дигән гыйбарә «диңгездә үлгән хайвандыр». Бу айәтнең гомуми мәгънәсенә су хайваннарының һәммәсе дә, әлбәттә, керәләр.

[1] су кешесе (إنسان الماء) – мифик мәхлук, су анасы. Әмма бу мәсьәлә байтак фәкыйһларның китапларында телгә алынган булган. Бу турыда Ибне Хәзем (м. 1064 вафат) үзенең «әл-Мөхәллә» исемле китабында, мәлики мәзһәб галиме булган Әд-Дәрир (м. VIII–IX) «әш-Шәрх әс-сагыйр»да, мәлики галим Әс-Сави (?) «Хашия»дә, хәнбәли мәзһәбле Әл-Мәрдави (м.1480 вафат) «әл-Инсаф»та, хәнәфи Әл-Кәсани (м. 587 вафат) «Бәдаигъ әс-санаигъ»та, хәнәфи Ибн Габидин (м.1836 вафат) «Рәдд әл-мохтар»да язган булганнар. Мәсәлән, Каһирәдә яшәгән Кәмалетдин Әд-Дәмиринең (м. 1405 вафат) «Олы хайваннарның яшәеше» исемле китабында болай дип язган: «Су кешесе кешегә охшаган, әмма аның койрыгы бар. Казвини әйткән: «Безнең заманда бер кеше шундыйларның берсен тотып алып килгән иде».

[2] су дуңгызы – дельфин.

[3] «үзегезнең вә юлчыларның рәхәте өчен диңгездә ауга чыгу һәм андагы ашамлыклар сезгә хәлал ителде» (5:96).

[4] бәхер – гарәп теленең бу сүзен «диңгез» диеп кенә тәрҗемә кылу аның мәгънәсен тарайта, чөнки, чынлыкта, әлеге сүз «олы су» мәгънәсенә ия. Болай булганда ул диңгез, океан кебек тозлы сулыкларны гына түгел, елга, күл кебек төче сулы сулыкларны да белдерә.

2) (وَهُوَ الَّذِي سَخَّرَ الْبَحْرَ لِتَأْكُلُواْ مِنْهُ لَحْمًا طَرِيًّا) (ән-Нәхел, 14) [1].

3) (وَمَا يَسْتَوِي الْبَحْرَانِ هَذَا عَذْبٌ فُرَاتٌ سَائِغٌ شَرَابُهُ وَهَذَا مِلْحٌ أُجَاجٌ وَمِن كُلٍّ تَأْكُلُونَ لَحْمًا طَرِيًّا) (әл-Мәлаикәтү, 12) [2].

Бу айәт кәримәләрдә ит гомуми мәгънәдә искә алынган. Хәлаллекне бары тик балыклар белән генә чикли алырлык бер генә дәлил дә Коръән кәримдә юк.

Су хайваннары хакында хәдисләрнең гыйбарәләре дә гомуми мәгънәгә ияләр:

1) «*Әбү Һөрәйрәдән хәбәр ителгәнчә, пәйгамбәр, саллә Аллаһу галәйһи вә сәлләмә: «Диңгезнең суы ару, андагы үләксә хәлалдер»,– дигән*». Хәдисне Әл – Җөмәга риваять иткән.

Бу хәдистә диңгездәге үләксә дә гомуми мәгънәдә искә алынган булып чыга. Диңгезнең һәр үләксәсе хәлал булса, аның һәр хайваны да, әлбәттә, һичнинди искәрмәсез, хәлал була.

2) Имам Даракутни «Сөнән»дә Җабир атлы сәхабәдән тапшырып риваять иткән: «*Диңгездә Аллаһ адәм баласы өчен пакь кыйлмаган һичбер җан иясе юк*».

Бөтен су хайваннарының хәлал булу әлеге хәдистә ачыктан-ачык бәян кыйлынган. Әмма шуңа карамастан, сәдат хәнәфия кашында су хайваннарының һәммәсе, әлбәттә, хәрамдер, бары тик балык җенесе генә ашарга яраклы хәлалдер. Балыктан башка диңгез терлеге начар имеш, хәбис имеш. (وَيُحَرِّمُ عَلَيْهِمُ الْخَبَآئِثَ)[3] дигән айәт кәримәнең гомуми мәгънәсенә су хайваннарының һәммәсе дә кергән имеш.

Әлбәттә, бу рәвешле дәлилләү куәтле түгел. «Су хайваннарының һәммәсе шакшы»,– диеп әйтү ул бары тик буш бер дәгъвадыр.

Хәдис китапларында су хайваннары хакында сәдат хәнәфия карашын исбат итә алырлык бер хәдис риваять кыйлынмышдыр: «*Ибне Гомәрдән хәбәр ителгәнгә күрә, пәйгамбәр,*

---

[1] «Ул сезнең аңардан саф ит ашый алуыгыз өчен олы суны буйсындырды» (16:14).

[2] «Ике олы су бер-берсенә тиң булмаслар: монысы татлыдыр, төчедер, аның суын эчү рәхәт; ә монысы тозлыдыр, әчедер. Икесеннән дә саф ит ашыйсыз» (35:12).

[3] «вә алар өчен шакшы нәрсәләрне хәрам итә» (7:157).

*саллә Аллаһу галәйһи вә сәлләмә, әйткән ки: «Безнең өчен ике төрле үләксә вә ике төрле кан рөхсәт ителгән. Ул ике үләксә саранча белән хуттыр*[1]*, ике кан исә – кара бавыр*[2] *белән белән бавырдыр*». Бу хәдисне Әхмәд белән Ибн Маҗә тапшырганнар һәм аның зәгыйфьлеге дә бар.

Бу хәдис «Ифадат әл-кирам»ның 9 нчы сәхифәсендә 11 нче хәдис буларак аңлатылган.

Әлеге хәдистә диңгезнең хәлал булган үләксәсе турында аңлатма бирелгәндә, бары тик *хут* дигән җан иясе искә алынган. Әгәр дә су хайваннары арасында балыктан башкалары да хәлал булса иде, хәлал булган үләксә бары тик балыклар белән генә чикләнелмәс иде.

Сәдат хәнәфия карашына күрә, әгәр балык үләксәсе су өстенә калкып чыгарлык кадәр искергән булса, ул хәрамдер. Чөнки Коръән кәримдә ризыкның «саф» булу, ягъни яңа булу шарты бар, ягъни ашаласы ризык искергән, бозыла башлаган булырга тиеш түгел, яңа пешкән, яңа әзерләнгән булырга тиеш. Җабир исемле сәхабә хәзрәтләреннән имам Әхмәд белән имам Әбу Давыт ошбу хәдисне риваять иткәннәр: «*Пәйгамбәр әйтте ки: «Диңгез калдырган, яки диңгезнең суы чигенгәннән соң яр буенда калган нәрсәләрне ашагыз, әмма анда үлеп су өстенә калкып чыккан нәрсәләрне ашамагыз*».

Бу хәдистә әйтелгәннәргә күрә, су өстенә калкып чыккан үләксә хәрамдер. Андыйларның хәрам булуы, әлбәттә, дөресрәк. Чөнки андый нәрсәләрнең хәстәлек сәбәбе белән улгән булып, яки чери башлавы аркасында агуланган булып, ашарга яраклы нәрсәләр җөмләсеннән бөтенләй чыккан булулары мөмкин. Су хайваннарының һәрберсен хәлал дип тану шәригать күзлегеннән мөмкин була ала. Ләкин, авыру аркасында үлгән мәййитәләрне[3], черегән һәм агуланган итләрне хәлал, дип әйтү шәригатьнең асыл нигезенә туры килми. Зарарлы булу ихтималы булган нәрсәләрне тәхрим итү шәри-

---

[1] хут – зур балык, кит.

[2] кара бавыр (селезенка), татарча талак дип тә атала, мәсәлән: талагы ташыды.

[3] мәййитә – мәет, үләксә.

гатьнең иң зур, асыл нигезедер. Нәрсәне дә булса ясаклауның, хәрам кыйлуның башка һичнинди сәбәбе юк. Хәмер аңа хас булган котылгысыз зарарлар аркасында; үләксә, кан – зыян китерү ихтималы аркасында тәхрим кыйлынганнар.

Су өстенә калкып чыккан үләксәләрне исәптән чыгарганнан соң, су хайваннары хакында маликиләрнең, шәфигыйләрнең, хәнбәлиләрнең мәзһәбләре кабул иткән карарларны дөресрәк дип, яхшырак дип табу Коръән кәримнең айәт кәримәләренә күбрәк туры килә.

(وَهُوَ الَّذِي سَخَّرَ الْبَحْرَ لِتَأْكُلُواْ مِنْهُ لَحْمًا طَرِيًّا) (ән-Нәхел, 14) [1] кебек айәт кәримәләрнең хөкеме белән, диңгез кадәр диңгез кешеләргә файда китерү өчен хезмәткә куелган булса, аңардан файдалануны су хайваннарының бары тик бер төре белән генә чикләү ни өчен кирәк?

Олы суда аулана торган җанварлар турында (أُحِلَّ لَكُمْ صَيْدُ الْبَحْرِ وَطَعَامُهُ) (әл-Маъидә, 96) [2] дигән гомуми төстәге гыйбарәләр иңгән икән инде, шул ауланачак нәрсәләр арасында бары тик берсен генә хәлал итеп күрсәтү нидән килә?

Дөрес, Коръән кәримдә су хайваннарыннан бары тик *хут*, дигәне искә алынган.

(واَسْأَلْهُمْ عَنِ الْقَرْيَةِ الَّتِي كَانَتْ حَاضِرَةَ الْبَحْرِ إِذْ يَعْدُونَ فِي السَّبْتِ إِذْ تَأْتِيهِمْ حِيتَانُهُمْ يَوْمَ سَبْتِهِمْ شُرَّعاً وَيَوْمَ لاَ يَسْبِتُونَ لاَ تَأْتِيهِمْ) (әл-Әгъраф, 163) [3].

(وَإِذْ قَالَ مُوسَى لِفَتَاهُ... آتِنَا غَدَاءنَا لَقَدْ لَقِينَا مِن سَفَرِنَا هَذَا نَصَبًا قَالَ أَرَأَيْتَ إِذْ أَوَيْنَا إِلَى الصَّخْرَةِ فَإِنِّي نَسِيتُ الْحُوتَ) (әл-Кәһеф, 62–63) [4].

---

[1] «Ул сезнең аңардан саф ит ашый алуыгыз өчен олы суны буйсындырды» (16:14).

[2] «диңгездә ауга чыгу һәм андагы ашамлыклар сезгә хәлал ителде» (5:96).

[3] «Аларга олы су буенда кайчандыр гөрләп торган карьйә турында сорау бир. Алар шимбә көнендә хәттин аштылар, чөнки шимбә көннәрендә яр буена балык (хийтан) өер-өер булып килә иде, ә башка көннәрдә килми иде» (7:163). Хийтан – «хут» сүзенең күплек саны шәкеле.

[4] «Менә Муса үзенең хезмәтчесенә әйтте: «…ашыйсы ризыгыбызны китер, инде дә ошбу сәфәребездә хәлдән тайдык. Егет: «Бер кыя астына сыенып ялга тукталганыбызны хәтерлисеңме? Шунда мин теге балыкны [хут] онытып калдырганмын»,– диде» (18:60,

Ләкин кыйссаларда очраклылык рәвешендә килгән хосусыйлык – ул гомуми мәгънәле гыйбарәләргә нигезләнгән хөкемнәрнең гомумилегенә зыян китерә алмый.

Дөрес, су хайваннары итенең зарарын сәдат хәнәфия гамәли тәҗрибәләр белән исбат итә алсалар иде, ул чакта хәлаллекне бары тик балыкларга гына карата дөрес дип дәгъва итә алырлар иде. Ләкин, әгәр дә бу эш шәригать чыганаклары карамагына калса, ул чыганаклар гомумилекне исбат итәләр. Бу мәсьәләдә нәрсәне дә булса хаслап аерып алу өчен нигез булырлык шәргый чыганак, нинди дә булса шәргый күрсәтмә юк, хәтта ишарә дә юк.

Коръән кәримнең катгый мәгънәле күрсәтмәләре нигезендә хәлал кыйлынган яхшы нәрсәләрне, файдалы казылмаларны, үсемлек-яшелчәне, хайваннарны бәян иттек. Дүрт мәзһәбнең карашларын да дәлилләре белән бергә китереп тәфсилләп аңлаттык. Һава хайваннары хакында хәнәфи, хәнбәли, шәфигый мәзһәбләренең; су хайваннары хакында мәлики, хәнбәли, шәфигый мәзһәбләренең карашларын отышлырак итеп күрсәтә алдык. Ягъни, һава хайваннары хакында мәликиләрне, су хайваннары хакында хәнәфиләрне тәнкыйть иттек. Эзләнүчеләргә, шәкертләргә файдасы булыр дигән өмет белән, Коръән кәримдә кешенең ризыгы хосусларында иңгән айәт кәримәләрнең һәрберсен бу китапта бәян итүне үзебезнең бурычыбыз иттек.

Шәригать исламиядә зарарлы хәбаъиснең, ягъни шакшы, начар нәрсәләрнең һәммәсе катгый сурәттә тәхрим кыйлынып, хәлаллек бары тик таййибаткә, ягъни яхшы нәрсәләргә хасланган дигән идек. Димәк, бары тик таййибат, ягъни яхшы нәрсәләр генә хәлалдер. Ләкин, таййибатнең хәлал булара билгеләнүе пәйгамбәребез рисаләтенең бары тик соңгы көннәренә хас булган, соңгы көннәрдә генә кабул ителгән карар түгел, бәлки рисаләт башланган әүвәлге көннәрдә үк инде таййибат хәлал иде. Һәм дә таййибатнең хәлаллеге исламияткә генә хас булган шәригать булмыйча, бәлки әүвәлге өммәтләрнең һәрберсендә дә яхшы нәрсәләр хәлал иде.

62–63).

(وَلِكُلِّ أُمَّةٍ جَعَلْنَا مَنسَكًا لِيَذْكُرُوا اسْمَ اللَّهِ عَلَى مَا رَزَقَهُم مِّن بَهِيمَةِ الْأَنْعَامِ) (әл-Хаҗ сүрәсе, 34) [1].

(وَلَكُمْ فِي الأَرْضِ مُسْتَقَرٌّ وَمَتَاعٌ إِلَى حِينٍ) (әл-Бәкара сүрәсе, 36) [2].

(يَا أَيُّهَا النَّاسُ كُلُواْ مِمَّا فِي الأَرْضِ حَلاَلاً طَيِّباً) (әл-Бәкара сүрәсе, 168) [3].

(يَا أَيُّهَا الرُّسُلُ كُلُوا مِنَ الطَّيِّبَاتِ وَاعْمَلُوا صَالِحًا) (әл-Мөэминүн, 51) [4].

(وَلَقَدْ آتَيْنَا بَنِي إِسْرَائِيلَ الْكِتَابَ وَالْحُكْمَ وَالنُّبُوَّةَ وَرَزَقْنَاهُم مِّنَ الطَّيِّبَاتِ) (әл-Җасия сүрәсе, 16) [5].

Болай булса, (الْيَوْمَ أُحِلَّ لَكُمُ الطَّيِّبَاتُ)[6] дигән айәт кәримәдә искә алынган хәлаллекне бары тик шул көннән башланган дип, бары тик ислам өммәтенә хас булган нәрсәдер, дип дәгъвалауның мәгънәсе ни?

Бәлагать, ягъни матур, төзек, аңлаешлы сөйләм вә язу кагыйдәләренең таләпләренә күрә, фигыльгә буйсынучы сүзләрнең фигыльнең алдына чыгуы чикләүне белдерә. Шундый шәкелдәге: (الْيَوْمَ أُحِلَّ)[7], дигән коръәни җөмлә белән: «*ухиллә әл-йәүмә*»[8], дигән фаразый[9] җөмлә арасында гарәп теле кагыйдәләре күзлегеннән караганда зур аерма бар. Беренче җөмлә чикләүне белдерә. Ягъни ул җөмлә: «элек хәлал түгел

[1] «Раббылары аларга ризык буларак биргән йорт хайваннарын чалыр алдыннан Аллаһ исемен зикер кыйлсыннар диеп Без һәр өммәткә йолалар билгеләдек» (22:34).

[2] «Сезнең өчен җир йөзендәдер билгеле бер вакыт дәвамында торыр урыныгыз вә кирәк-яракларыгыз» (2:36).

[3] «Әй, кешеләр! Җир йөзендәгеләрдән хәлал һәм яхшы булганнары белән тукланыгыз» (2:168).

[4] «Әй, рәсүлләр! Яхшы булган нәрсәләр белән тукланыгыз вә игелек кыйлыгыз» (23:51).

[5] «Без Исраил токымына Китап, Хөкем кыйлу хакы һәм пәйгамбәрлек бирдек һәм аларны яхшы нәрсәләр белән ризыкландырдык» (45:16).

[6] «Бүгеннән башлап сезнең өчен яхшы нәрсәләр хәлал ителде» (5:5).

[7] «әл-йәүмә ухиллә» (5:5 нче айәтнең башлам сүзләре. Мәгънәсе: «Бүгеннән башлап… хәлал ителде».

[8] «Бүгенгә хәлал ителде»).

[9] фаразый – уйдырма, теоретик, гипотетик.

иде, бары тик бүген хәлал кыйлынды», дигән мәгънәгә ия. Әмма соңгы җөмләдә чикләү юк.

Дөрес, (الْيَوْمَ أَكْمَلْتُ لَكُمْ دِينَكُمْ)[1], дигән айәт кәримәдә үткән заманга нисбәтән чикләү мөмкин. Ягъни, элек дин кямил түгел иде, ул исламият барлыкка килгән көннәрдә генә кямил кыйлынды, дигән мәгънә килеп чыга. Шуңа күрә, диннең кямиллеккә ирештерелүен исламиятнең барлыкка килгән көне белән чикләү мөмкин.

Дөрес, (الآنَ خَفَّفَ اللهُ عَنكُمْ وَعَلِمَ أَنَّ فِيكُمْ ضَعْفًا)[2], дигән айәт кәримәдә киләчәккә нисбәтән чикләү мөмкин. Чөнки йөкне яки вазифаны җиңеләйтү әзерлек булмаган сәгатьләрдә генә урынлы була ала. Әмма, ашарга рөхсәт ителгән яхшы нәрсәләрнең хәлаллеге исламият барлыкка килгәндә дә, рисаләтнең соңгы көннәренә дә хас түгел иде. Алай булгач, чикләүнең мәгънәсе ни?

Бөтен тырышлыкларын Коръән кәримнең сөйләм осталыгына, бәлагать-риторикасына, гарәбиятенә[3] багышлаган «Казый» кебек, «Кәшшаф»[4] кебек тәфсирләр сөйләм осталыгының бу мөһим күренеше хакында, нидәндер, дәшми калганнар. Зур әһәмияте булган бу чикләү хакында тәфсирләребезнең һичберендә бер сүз дә юк.

Фигыльгә буйсындырылган сүзләрнең алга чыгуының чикләүдән башка файдаларын әдәп әһеленең бәяннарыннан барлап-санап чыкканнан соң, бу айәтнең могҗизави төзелешенә диккать белән бактым. Чикләү файдасыннан башкасы һичбер айәтнең мәгънәсенә, максатына туры килмәде. Шуңа күрә, чикләүнең төрләрен эзләдем; нәтиҗәдә таптым:

[1] «Бүген сезнең өчен динегезне кямиллеккә җиткердем» (5:3).

[2] «әледән башлап Аллаһ йөгегезне җиңеләйтте, чөнки Ул сездә зәгыйфьлек барын белде» (8:66).

[3] гарәбият – әлеге сүзнең мәгънәсен Коръәннең асыл теле булган гарәп теленең грамматикасы, синтаксисы, кагыйдәләре, нечкәлекләре һәм гарәпләргә хас булган яшәү рәвешенең үзенчәлекләре, гореф-гадәтләре тәшкил итә.

[4] «Кәшшаф» – Мәхмүд әз-Замахшаринең (1075–1144) «Әл-Кәшшаф ган хакаикъ гавамид әт-тәнзил вә гуйун әл-акавил фи вөдҗүһ әт-тәэвил» исемле Коръән тәфсире.

Яхшы нәрсәләр өммәтләрнең һәммәсе өчен һәрвакыт хәлал иде, рисаләтнең соңгы көннәренә генә хас булган бер күренеш түгел иде. Ләкин ул хәлаллек я ирекле куллану юлы белән, яки «гафу» юлы белән булып, хөкем куәте белән түгел иде. Ягъни, күктән иңгән китапта таййибатнең хәлаллеге турысында килгән илаһи фәрманның хөкеме белән түгел иде.

Коръән кәримдә иҗтимагый тормышка караган хөкемнәр аңлатылды; хәрам, хәлал хакында тәфсилле махсус айәтләр иңде; ислам бәрәкәте белән кешелек дөньясы дини кямиллегенә ирешти. Элек ул бөтенлек, ул кямиллек юк иделәр.

Шуңа күрә, рисаләтнең соңгы көннәрендә, «әл-Маъидә» сүрәсенең башында чикләү турындагы айәт кәримәләр иңде:

1) (الْيَوْمَ أَكْمَلْتُ لَكُمْ دِينَكُمْ)[1].

Ягъни, бары тик исламият барлыкка килгән көндә кешелек дөньясының дине кямиллегенә җиткерелде.

2) (الْيَوْمَ أُحِلَّ لَكُمُ الطَّيِّبَاتُ)[2] (әл-Маъидә, 5).

Ягъни: ашарга яраклы булган яхшы нәрсәләр сезгә, илаһи фәрман куәте белән тик бу көндә хәлал кыйлынып, динегезнең кямиллегенә янә бер кямиллек бары тик шул көнне кушылды. Дөрес, нәрсәне дә булса «гафу» итү юлы белән хәлал кыйлу Аллаһның зур йомшаклык күрсәтүе булып тора. Ләкин, ашарга яраклы булган яхшы нәрсәләрнең илаһи фәрман куәте белән хәлал ителүе – ул тагын да зуррак мәртәбәдер, кямиллекнең тагын да югарырак билгеседер.

(الْيَوْمَ أُحِلَّ لَكُمُ الطَّيِّبَاتُ)[3] дигән айәт кәримәдә чикләү нәкъ әнә шул үзенчәлеккә ия булырга мөмкин.

Мал-туарның йортта асрала торган төрләре, һәм дә, гомумән, яхшы нәрсәләр кешеләргә хәлал иде, хәзер дә хәлалдер. Хәлал хайваннарның сөтләре кебек, аларның йөк ташуга яраклы булулары кебек барлык файдалары да, әлбәттә, хәлал-

[1] «Бүген сезнең өчен динегезне кямиллеккә җиткердем» (5:3).

[2] «Бүгеннән башлап сезнең өчен яхшы нәрсәләр хәлал ителде» (5:5).

[3] «Бүгеннән башлап сезнең өчен яхшы нәрсәләр хәлал ителде» (5:5).

дыр. Ләкин җаһилият[1] чоры гарәпләре дөяләрнең кайберләрен *бәхира*, *саъибә*, *хама*, дигән исемнәр белән, сарыкларның кайберләрен *вәсыйлә*, дигән исем белән аерымлап, ул хайваннарга хас булган бөтен файдаларны үзләре өчен хәрам итә торган булганнар.

Җаһилият чорының бу гадәтләрен гамәлдән чыгару өчен, Коръән кәримдә «әл-Маъидә» сүрәсендә: (مَا جَعَلَ اللّهُ مِن بَحِيرَةٍ وَلاَ سَآئِبَةٍ وَلاَ وَصِيلَةٍ وَلاَ حَامٍ وَلَـكِنَّ الَّذِينَ كَفَرُواْ يَفْتَرُونَ عَلَى اللّهِ الْكَذِبَ وَأَكْثَرُهُمْ لاَ يَعْقِلُونَ) (103) [2], дигән аять кәримә иңгән.

Ягъни, хайваннарның файдаларын тәхрим кыйлу борынгы шәригатьләрнең һичберсендә юк иде. Шәригать чыганакларында булмаган нәрсәләрнең очын Шәригъиең үзенә тоташтырып кую ул – аңа яла ягудыр. Хәлал булган файдаларны тәхрим кыйлу, гомумән, хәрамдер: (قَدْ خَسِرَ الَّذِينَ قَتَلُواْ أَوْلاَدَهُمْ سَفَهًا بِغَيْرِ عِلْمٍ وَحَرَّمُواْ مَا رَزَقَهُمُ اللّهُ افْتِرَاء عَلَى اللّهِ قَدْ ضَلُّواْ وَمَا كَانُواْ مُهْتَدِينَ) (әл-Әнгам, 140) [3].

Коръән кәримдә «әл-Әнгам» сүрәсенең (136–138–139) аять кәримәләрендә җаһилият дәвере гарәпләренең дини гадәтләре, ялгыш дәгъвалары китерелгән. Ул дини гадәтләрне, ялгыш дәгъваларны юкка чыгару юлында Коръән кәримдә ике аять иңгән иде.

Берсен китердек. Анысы «әл-Маъидә» сүрәсендәге (مَا جَعَلَ اُللهُ مِن بَحِيرَةٍ وَلَا سَآئِبَةٍ وَلَا وَصِيلَةٍ وَلَا حَامٍ)[4], дигән аять кәримә иде.

---

[1] җаһилият (наданлык, белемсезлек) – гарәпләрнең аларга ислам дине бирелгәнгә кадәр булган халәтләре.

[2] «Аллаһ ни бахирәне, ни саибәне, ни вәсыйләне, ни хамәне булдырмады. Ләкин шөкер кыйлмаучылар Аллаһ турысында алдап аңа яла ягалар һәм аларның күбесе уйламыйлар» (5:103).

[3] «Белемсезлекләре вә ахмаклыклары аркасында балаларын үтерүчеләр, Аллаһка яла ягып Аның хәлал кыйлганнарын хәрам итүчеләр олы хәсрәттә. Алар тәмам адаштылар вә тугъры юлдан баручы түгелләр» (6:140).

[4] «Аллаһ ни бахирәне, ни саибәне, ни вәсыйләне, ни хамәне булдырмады» (5:103).

Икенчесе «әл-Әнгам» сүрәсендә килгән (قُل لاَّ أَجِدُ فِي مَا أُوْحِيَ إِلَيَّ مُحَرَّمًا عَلَى طَاعِمٍ يَطْعَمُهُ إِلاَّ أَن يَكُونَ مَيْتَةً أَوْ دَمًا مَّسْفُوحًا أَوْ لَحْمَ خِنزِيرٍ فَإِنَّهُ رِجْسٌ أَوْ فِسْقًا أُهِلَّ لِغَيْرِ اللّهِ بِهِ)[1] (145) дигән айәт кәримәдер.

Ягъни, яхшы нәрсәнең асыл сыйфаты аның хәлал булуыдыр. Китап кәримдә хәрамлеге бәян кыйлынмаган яхшы нәрсәләрнең һәрбере, әлбәттә, хәлал була. Коръән кәримдә хәрамлеге бәян кыйлынган нибары дүрт нәрсә бар. Болардан башка яхшы нәрсәләрнең һәммәсе, әлбәттә, хәлал булачак.

Әлеге айәт кәримә ул, (وَمَا لَكُمْ أَلاَّ تَأْكُلُواْ مِمَّا ذُكِرَ اسْمُ اللّهِ عَلَيْهِ وَقَدْ فَصَّلَ لَكُم مَّا حَرَّمَ عَلَيْكُمْ) (әл-Әнгам, 119) [2], дигән айәт кәримә кебек үк, чын мәгънәдә аңлатып бирүне күздә тоткан үтенечтер.

Әлеге ике айәт кәримәдә искә алынган дәлил ике нигезгә корылган: 1) яхшы нәрсәләрнең гомумән хәлал булуы, 2) хәрамнең Коръән кәримдә тәфсилләп аңлатылган хәрамнәр белән генә чикләнелгән булуы. Ике нигезнең һәрбере, әлбәттә, катгыйдыр. Саннары бик аз булган хәрам нәрсәләр тикшерелеп чыгып барланганнан соң, теге яки бу нәрсә хәрам әйберләр арасында булмаса, табылмаса – аның хәлал булуы шуның белән, әлбәттә, раслана.

(قُل لاَّ أَجِدُ فِي مَا أُوْحِيَ إِلَيَّ مُحَرَّمًا عَلَى طَاعِمٍ يَطْعَمُهُ إِلاَّ)[3] дигән айәт кәримәдәге чикләү әле һаман да гамәлдә, ул һичбер хәдис белән дә, һичбер айәт белән дә гамәлдән чыгарылмаган, ягъни мәнсух булмаган. Дәлил һаман да дәлил булып кала бирә. Соңрак иңгән тыю, әгәр дә ул бар икән, шушы айәтнең бер сүзен дә, бер хәрефен дә кире какмый. Дөрес, хөкемнәр әледән

---

[1] «Әйт: Миңа иңдерелгән вәхийдә ашаучы өчен аның ашый торган тәгамнары арасында мин үләксә, агызып алынган кан, шакшылыкның үзе булган дуңгыз ите һәм Аллаһыдан башка бер нәрсәгә атап чалынган нәрсәләрдән башка хәрам булган нәрсәләр тапмыйм» (6:145).

[2] «Ни булды сезгә? Аллаһ… сезгә нинди нәрсәләрне хәрам иткәнен тәфсилләп аңлатып биргәннән соң да Аның исеме әйтелеп чалынган мал-туар итен күрә торып ашамыйсыз!» (6:119).

[3] «Әйт: Миңа иңдерелгән вәхийдә ашаучы өчен аның ашый торган тәгамнары арасында мин… башка хәрам булган нәрсәләр тапмыйм» (6:145).

әле иңеп торалар иде. Хәрамлеге әүвәлге айәт кәримәләрдә бәян кыйлынмаган нәрсәләрнең кайберләрен аннан соңгы көннәрнең берсендә тәхрим итү, әлбәттә, мөмкин иде. Тик, айәтнең иңүеннән соң бераз вакыт узгач кайбер нәрсәләр тәхрим кыйлынса, айәтнең дәлил булуы юкка чыкмый, аның хөкеме гамәлдән чыгарылмый.

Әгәр дә айәт кәримәдә хәлал булуы дәгъва ителеп, хәрам булуы инкяр ителгән нәрсәләрнең ахырда хәрам булуы турысында бер хөкем иңсә иде, яки аның хәлал булуы инкяр ителсә иде, айәтнең хөкеме, әлбәттә, дөрес булмас иде. Ләкин, мондый нәрсә булмаган. Ул гына да түгел, (قُل لاَّ أَجِدُ)[1] дигән айәт кәримә иңгәннән соң яңа бер тыюның гамәлгә кертелүе дә мәгълүм түгел.

Дөрес, ул хәдиснең бәянына күрә, йорт ишәкләре Хәйбар көнендә[2] хәрам кыйлынганнар. Ләкин, бу: «аларның хәрамлеге Хәйбар көннәрендә бәян кыйлынган», дип әйтү мәгънәсендә булса кирәк, чөнки ул (فَإِنَّهُ رِجْسٌ)[3], дигән җөмлә белән расланган. Йорт ишәгенең ите салынган савыт-сабаны юдырту турындагы фәрман да моңа дәлиллек итә. Әгәр дә йорт ишәге элек хәлал булган булса иде, ул начар нәрсә булмас иде, савыт-сабаларны юу да кирәк булмас иде. Димәк, йорт ишәге һәрвакыт хәрам булган, тик Хәйбар көннәрендә, ниндидер бер сәбәп аркасында, аларның хәрам булуы бәян ителгән. Ягъни, бу очракта, хәрам булу күптәнге нәрсә булган, әмма, бу турыда белдерү яңа нәрсә булган.

Рисаләт дәверендә мондый нәрсәләр еш булып торган. Ерткыч хайваннарны, тырнаклы кошларны тәхрим итү дә

[1] «Әйт:… тапмыйм» (6:145).

[2] Хәйбар көне – Хәйбар Мәдинәдән төньякка таба якынча 140–150 чакрым ераклыкта урнашкан уңдырышлы үзән (оазис). Мәдинәдә яшәгән бану надир исемле яһүд ыруы мөселманнарга карата кыйлган хыянәтләре өчен 625 нче елда бирегә куыла. Әмма 627 нче елда алар яңадан мөселманнарга каршы дошманлык итә башлыйлар. Моңа җавап йөзеннән 628 нче елның май аенда Мөхәммәт пәйгамбәр (ﷺ) Хәйбар яһүдләренә каршы газават явын башлап, аларны тар-мар итә һәм буйсынырга мәҗбүр итә.

[3] «шакшылыкның үзе булган» (6:145).

шул җөмләдәндер. Хәрамлек күптәнге булса да, аны бәян итү яңадыр.

(قُل لاَّ أَجِدُ فِي مَا أُوْحِيَ إِلَيَّ مُحَرَّمًا عَلَى طَاعِمٍ يَطْعَمُهُ إِلاَّ)[1] дигән айәт кәримәдә тәфсирләр тарафыннан игътибардан читтә калдырылган бер җөмлә бар, ул да булса: (عَلَى طَاعِمٍ يَطْعَمُهُ)[2], дигән җөмлә.

Дөрес итеп төзелгән, үтемле һәм тәэсир итү көченә ия булган сөйләмдә бер генә сүз дә ни урынсыз булмый, ни тик-томалдан әйтелми. Һәрбер сүзгә мөһим бер мәгънә, зур әһәмият, әлбәттә, хас. Коръән кәрим кебек могъҗизави сөйләмдә һәр сүзнең зур әһәмияткә ия булуы, әлбәттә, катгый шарттыр.

(محرماعليكم)[3] дип әйтү дә җитәр иде кебек. Нигә соң (عَلَى طَاعِمٍ)[4] дигән сүзтезмә сайланылган? Ни өчен (يَطْعَمُهُ)[5] дигән аергыч кушылган?

Сүзләрнең үзенчәлекләрен, килеш-төрләнешләрен, укылышларын зур тырышлык белән бәян итүче разилар[6], казыйлар[7] мондый хосусларда, гадәттә, бер ни дә әйтмиләр. Минем фикеремә күрә, (عَلَى طَاعِمٍ)[8] дигән сүзтезмәнең дә, аның (يَطْعَمُهُ)[9] дигән җөмлә белән аерымлануының да гаять мөһим булган берничә файдалы үзенчәлеге бар:

1) (عَلَى طَاعِمٍ)[10] дигән сүзтезмә ярдәмендә хәрамлекнең нәрсәне күздә тотуы тәгаен ителә. Ягъни, үләксә кебек, яки

---

[1] «Әйт: Миңа иңдерелгән вәхийдә ашаучы өчен аның ашый торган тәгамнары арасында мин… башка хәрам булган нәрсәләр тапмыйм» (6:145).

[2] «ашаучы өчен аның ашый торган тәгамнары» (6:145).

[3] «Сезнең өчен хәрам ителгән».

[4] «ашаучы өчен» (6:145).

[5] «аның ашый торган тәгамнары» (6:145).

[6] разилар – биредә танылган фикер иясе, кәламчы, «Мәфатих әлгайб» («Күренми торганның ачкычлары») исемле тәмамланмаган Коръән тәфсирен язучы Фәхретдин Әбү Габдуллаһ Мөхәммәд ибне Гомәр әр-Разины (м. 1149–1209) күздә тота.

[7] казыйлар – биредә Муса әфәнде фәлсәфәче, казый, «Тәфсир әл-Бәйдави» исемле тәфсирне язган Насыйретдин Әбү Сәгыйд Габдуллаһ ибне Гомәр әл-Бәйдавины (м.1286 вафат) күздә тота.

[8] «ашаучы өчен» (6:145).

[9] «аның ашый торган тәгамнары» (6:145).

[10] «ашаучы өчен» (6:145).

кан кебек хәрамнәрнең бары тик ашарга яраксыз булуы, тыелган булуы күрсәтелә. Бу нәрсәләрнең нинди дә булса башка файдалары булса, ул файдаларны куллану, әлбәттә, хәлал була. Бу гыйбарә ярдәме белән, (إِنَّمَا حَرَّمَ عَلَيْكُمُ الْمَيْتَةَ)[1] кебек айәт кәримәләрнең дә мәгънәләре тәгаен кыйлына ала булса кирәк.

Бу файда, икътисад ноктасыннан карасак та, гаять бөек әһәмияткә ия. Безнең фәкыйһлар һич тә тартынып тормыйча, ашарга ярамаган хәрам нәрсәләргә хас булган файдаларны да тәхрим иткәннәр. (عَلَى طَاعِمٍ)[2] дигән сүзтезмәнең бәянына күрә, ашалуы хәрам кыйлынган нәрсәләргә хас булган файдаларны куллану хәлал булып чыга. Мәсәлән, үләксә хәрамдер, үләксә итен ашау тыелган. Ләкин аның тиресе, ите, бәлки һәр парчасы малдыр. Аны сатып җибәрү, сатып алу рөхсәт ителә, ягъни аңа хас булган файдаларны куллану хәлалдер.

2) (عَلَى طَاعِمٍ)[3] дигән сүзтезмә ярдәмендә хәрамнең нәрсәгә караган булуы, нәрсәне күздә тотуы белдерелә. Ләкин, чикләүнең даирәсе әле белдерелмәгән. Чикләүнең даирәсе (يَطْعَمُهُ)[4] дигән җөмлә ярдәмендә тәгаен ителә. Ягъни, гадәттә ашала торган ашамлыклар арасында бары тик шушы дүрт нәрсә хәрамдер. «Гадәттә ашала торган» ризык даирәсеннән чыккан нәрсәләр чикләү даирәсеннән дә тышта калалар. Шуңа күрә, нәҗасәт, шакшы-хәбаъис, ерткыч хайваннар вә кошлар, төрле хәшәрәтләр чикләүнең даирәсенә кермиләр; боларның айәт кәримәдә саналган дүрт нәрсә исәбенә кертелмәүләре сәбәпле хәлал булмаулары һәм була алмаулары да көн кебек ачык.

Безнең бәяныбызга күрә, (قُل لاَّ أَجِدُ فِي مَا أُوْحِيَ إِلَيَّ مُحَرَّمًا عَلَى طَاعِمٍ يَطْعَمُهُ إِلَّا)[5] дигән айәт кәримә мәнсух та түгел, махсус та түгел. Ягъни, ул мәнсух буларак гамәлдән чыгарылмаган,

---

[1] «Чынлыкта, Ул сезнең өчен үләксәләрне хәрам итте» (2:173).

[2] «ашаучы өчен» (6:145).

[3] «ашаучы өчен» (6:145).

[4] «аның ашый торган тәгамнары» (6:145).

[5] «Әйт: Миңа иңдерелгән вәхийдә ашаучы өчен аның ашый торган тәгамнары арасында мин… башка хәрам булган нәрсәләр тапмыйм» (6:145).

махсус рәвештә нинди дә булса бер генә нәрсә турында да әйтми. Айәт кәримәдән аңлашылган чикләү гамәлдән чыгарылмаган. Ул һаман мәңге-бакыйдыр. Нәҗасәтнең, хәбаъиснең, хәшәрәтләрнең, ерткыч хайван вә кошларның хәрамлеге чикләүнең гамәлдән чыгарылмаган булуына да, мәңге бакыйлыгына да каршы килми. Ул чикләүнең башы Мәдинәдә иңгән «әл-Бәкара» сүрәсенең 173 нче айәтендә дә, Мәккәдә иңгән «ән-Нәхел» сүрәсенең 115 нче айәтендә дә бардыр.

Димәк, хәрамлекне шушы дүрт нәрсә белән чикләү рисаләт гасырының башыннан ахырына кадәр дәвам иткән. Хәмернең дә, хәбаъиснең дә хәрамлеге да рисаләт дәвере кадәр дәвам иткән. Хәмернең, хәбаъиснең хәрам булуы хакында күпсанлы айәт кәримәләр һәм Мәккәдә, һәм Мәдинәдә иңгәннәр. Нәҗасәтнең хәрам ителүе рисаләтнең нәкъ башында бер дини заруриилык кебек булган: (فَاهْجُرْ وَثِيَابَكَ فَطَهِّرْ وَالرُّجْزَ)[1]. Мәккәдә иңмеш «әл-Әнгам» сүрәсендә, (قُل لاَّ أَجِدُ)[2] дигән айәт кәримәдә дуңгызның хәрамлеге (فَإِنَّهُ رِجْسٌ)[3] дигән җөмлә белән аңлатылуы нәтиҗәсендә, нәҗасәттә хәрамлекнең котылгысыз булуы мәгълүм булып киткән. Һәрбер нәҗес хәрам булмаса иде әгәр, бу аңлату да урынсыз булыр иде. Рисаләт гасырында хәрамнең даирәсе киң иде, Мәккәдә чикләү турында инде берничә мәртәбә иңгән айәт кәримәләр Мәдинәдә яңадан иңделәр. Биредә үзара каршылык, үзара ярашмау кебек берни дә юк иде. Булуы да мөмкин түгел иде.

Ләкин Шәригъ хәкимнең үзенә дә, телне яхшы белүче гарәпләргә дә күренмәгән каршылыкларны кайбер фәкыйһлар, кайдандыр, күреп алдылар. Күреп алдылар да, чикләү турындагы айәт кәримәләрне я нәсех итеп гамәлдән чыгардылар, я аларга махсуслык төсе бирделәр. Шул фәкыйһларның кайберләре хәрам ителгән дүрт нәрсәдән тыш башка нәрсәләрнең хәлаллеген бетереп, шул хөкемнәренә чикләү турындагы айәт

---

[1] «Кием-салымыңа килгәндә исә – аны пакьла, һәм шакшыдан ерак тор» (74:4–5).

[2] «Әйт:… тапмыйм» (6:145).

[3] «шакшылыкның үзе булган» (6:145).

кәримәләр белән дәллилләр китерделәр. Фәкыйһларның бу хәрәкәтләре хакыйкатькә һич тә туры килми иде.

Нинди булса да нәрсә аңлаешлы, төзек вә матур сөйләм гыйбарәләре белән дәлилләнгәндә, бәян итүнең әдәп вә кагыйдәләренә, сөйләүченең әйтергә теләгәненә, ул әйтергә теләнгән мәгънәнең нинди даирәгә караган булуына, урынның таләп вә шартларына, кулланылышның үзенчәлекләренә игътибар итәргә тиешле. Юкса, сүзләрнең бары тик үз башларына булган мәгънәсен, бары тик тышкы күренешләрен игътибарга алып алдансаң әгәр, андый дәлилләү һичбер вакыт дөрес бумаячак, сөйләүченең әйткән сүзе дә күпчелек очракларда хата булачак.

Болай булганда, «әл-Әхкяф» сүрәсендә Гад кавеме хакында: (فَأَصْبَحُوا لَا يُرَى إِلَّا)(رِيحٌ فِيهَا عَذَابٌ أَلِيمٌ تُدَمِّرُ كُلَّ شَيْءٍ بِأَمْرِ رَبِّهَا)[1], кебек; (مَسَاكِنُهُمْ)[2], кебек; «ән-Нәмел» сүрәсендә (وَإِذَا وَقَعَ الْقَوْلُ عَلَيْهِمْ أَخْرَجْنَا لَهُمْ دَابَّةً مِّنَ الْأَرْضِ تُكَلِّمُهُمْ أَنَّ النَّاسَ كَانُوا بِآيَاتِنَا لَا يُوقِنُونَ)[3] кебек; Сәба иле мәликәсе хакында (وَأُوتِيَتْ مِن كُلِّ شَيْءٍ)[4] кебек; «әл-Әгъраф» сүрәсендә Тәурат хакында (وَكَتَبْنَا لَهُ فِي الْأَلْوَاحِ مِن كُلِّ شَيْءٍ)[5] кебек бөтенлекне, гомумилекне белдерә торган айәт кәримәләрнең берсе дә дөрес булмас иде. Чөнки ошбу айәт кәримәләрдә бәян ителергә тиеш булган мәгънәнең даирәсен белдерә торган гыйбарәләр белән гомумилекне белдерә торган гыйбарәләренең үз башларына дәлиллек итү биләмәләре гаять ачык рәвештә бер-берсеннән аерылып тора. Әйтелергә тиешле булган мәгънәнең даирәсе – дәлилнең миллиардтан берсенә дә тиң түгел. Ягъни, мәсәлән, (كُلِّ شَيْءٍ)[6] дигән гыйбарә

[1] «…үзендә каты газап булган җил. Раббыңның әмере белән ул һәрнәрсәне җимерә» (46:24–25).

[2] «…иртән баксалар – җимерек каралты-кураларыннан башкасы күренми» (46:25).

[3] «Алар хакындагы сүз чынбарлыкка ашкач, алар өчен җирдән бер җанвар чыгарырбыз ки, ул җанвар аларга кешеләрнең Безнең айәтләребезгә һич шикләмәстән инанмаулары турында әйтәчәк» (27:82).

[4] «һәрнәрсәнең иясе ителгән» (27:23).

[5] «Без аның өчен һәрнәрсәне ләүхәләргә язып бирдек» (7:145).

[6] «һәрнәрсә».

бөтен барлыкны үз эченә сыйдыра. Сәба иле мәликәсенең милке исә, (كُلِّ شَيْءٍ)[1] дигән гыйбарәнең колачына нисбәтән тулы мәгънәдә сыфырдыр[2], ягъни юк дәрәҗәсендәдер.

Сөйләмдә сүзләрнең үз башларына дәлил булуларын нигез итеп алу хатадыр, бозыклыктыр. Бу бозык нигезне салганнан соң, сөйләмне хаслау юлы белән ислях кыйлу хәйләсе бозык нигез өстенә яңа бер бозык бина кору кебектер. Чөнки (وَأُوتِيَتْ مِن كُلِّ شَيْءٍ)[3] дигән җөмләдә чикләнелмәгән күплекне зикер кыйлып та, юкка тиң булган азлыкны күздә тоту акылның мәртәбәсенә һичбер сурәттә мөнасыйп түгел. Андый сөйләмдә бәлагатьтән[4] бер әсәр дә юк. Искә алынган (أَنَّ النَّاسَ كَانُوا بِآيَاتِنَا لَا يُوقِنُونَ)[5] кебек җөмләләрдә Аллаһның бөек айәтләренә иман иткән миллиардлаган кешеләрне санга сукмау бәлагатьнең дә, хакыйкатьнең дә таләпләренә туры килми.

Хаслау, усул-ы дин белгечләренең бәянына күрә, гомумилекне белдергән формаларны катгыйлыктан да мәхрүм итә. Хасланган гомумилек формалары дәлил була алу мәртәбәсеннән дә колак кага. Усул-ы дин белгечләренең (ما من عموم الا وقد خص منه البعض)[6] дигән сүзләрен дә игътибарга алсак, ислам шәригатендә катгый бер дәлилнең булмавы тиешле булып чыга. Ул куркынычларның һәрбере сөйләмдә сүзләрнең үз башларына дәлил була алуларын нигез итеп алу хатасыннан үсеп чыгып, ахырда шуны мәҗбүриләштергән олы хатадыр.

Минем бәяныма күрә Коръән кәримнең гомумләрендә тәхсыйс, ягъни хаслап аеру юк. Хәтта Коръән кәримнең (وَأُوتِيَتْمِن كُلِّ شَيْءٍ)[7] кебек гомумләре дә махсус түгелдер. Сөйләмнең колачы – мәкамына күрә, сөйләүченең әйтергә

[1] «һәрнәрсә»

[2] сыфыр (гарәп.) – ноль.

[3] «һәрнәрсәнең иясе ителгән» (27:23).

[4] бәлягать – матур, төзек, тәэсирле һәм аңлаешлы булган сөйләм; риторика.

[5] «…кешеләрнең Безнең айәтләребезгә һич шикләнмәстән инанмаулары…» (27:82).

[6] ма мин гомумин илла ва кад хасса мин-һу әл-багду, ягъни: Бер өлеше хаслап аерымланмаган гомумилек юктыр.

[7] «һәрнәрсәнең иясе ителгән» (27:23).

теләгәненә буйсына. Сөйләмнең дәләләте дә сөйләүченең әйтергә теләгәненә иярә. Сөйләүченең ни әйтергә теләгәне һәрвакыт сийак-ы кәламдан, ягъни контексттан мәгълүм була.

Мәсәлән, җаһилият дәверендә гарәпләр, я булмаса, гомумән кешелек дөньясы, хәлал булган нәрсәләрнең, хәлал булган файдалы нәрсәләрнең кайберләрен хәрам дип таныган булса, бу тәкъдирдә Коръән кәримнең:

(يَا أَيُّهَا الَّذِينَ آمَنُواْ كُلُواْ مِن طَيِّبَاتِ مَا رَزَقْنَاكُمْ وَاشْكُرُواْ لِلّهِ إِن كُنتُمْ إِيَّاهُ تَعْبُدُونَ إِنَّمَا حَرَّمَ عَلَيْكُمُ الْمَيْتَةَ وَالدَّمَ وَلَحْمَ الْخِنزِيرِ وَمَا أُهِلَّ بِهِ لِغَيْرِ اللّهِ) (әл-Бәкарә сүрәсе, 172) [1]

(فَكُلُواْ مِمَّا رَزَقَكُمُ اللّهُ حَلالاً طَيِّبًا وَاشْكُرُواْ نِعْمَتَ اللّهِ إِن كُنتُمْ إِيَّاهُ تَعْبُدُونَ إِنَّمَا حَرَّمَ عَلَيْكُمُ الْمَيْتَةَ وَالْدَّمَ وَلَحْمَ الْخَنزِيرِ وَمَا أُهِلَّ لِغَيْرِ اللّهِ بِهِ) (ән-Нәхел сүрәсе, 114) [2].

(قُل لاَّ أَجِدُ فِي مَا أُوْحِيَ إِلَيَّ مُحَرَّمًا عَلَى طَاعِمٍ يَطْعَمُهُ إِلاَّ أَن يَكُونَ مَيْتَةً أَوْ دَمًا مَّسْفُوحًا أَوْ لَحْمَ خِنزِيرٍ فَإِنَّهُ رِجْسٌ أَوْ فِسْقًا أُهِلَّ لِغَيْرِ اللّهِ بِهِ) (әл-Әнгам, 145) [3], дигән айәт кәримәләрдә хәрам кыйлынган нәрсәләрне бары тик бу дүрт нәрсә белән чикләү бөтен яхшы нәрсәләрнең хәлаллегенә һәм дә яхшы нәрсәләрне тәхрим кыйлуның ялгышлыгына кешеләрне юнәлтү мәгънәсендә иңгән булып чыга. Ягъни, «бөтен таййибат хәлалдер, бары тик шушы дүрт нәрсә хәрамдер», дигән мәгънәдә була. Әгәр дә югары-

---

[1] «Әй, иман китергәннәр кешеләр! Сезгә ризык итеп бирдегемез яхшы нәрсәләр белән тукланыгыз һәм Аллаһыга шөкер кыйлыгыз, әгәр дә бары тик Аңа гына гыйбадәт кыйласыз икән! Чынлыкта, Ул сезнең өчен үләксәне, канны, дуңгыз итен һәм дә Аллаһыдан башка бер нәрсәгә атап чалынганнарны хәрам кыйлды» (2:172).

[2] «Аллаһ сезгә хәлал вә яхшы нәрсәләр буларак ризык итеп биргән нәрсәләр белән тукланыгыз. Аллаһның нигъмәтләре өчен шөкер кыйлыгыз, әгәр дә бары тик Аңа гына гыйбадәт кыйласыз икән! Чынлыкта, Ул сезнең өчен үләксәне, канны, дуңгыз итен һәм дә Аллаһыдан башка бер нәрсәгә атап чалынганнарны хәрам кыйлды» (16:114).

[3] «Әйт: Миңа иңдерелгән вәхийдә ашаучы өчен аның ашый торган тәгамнары арасында мин үләксә, агызып алынган кан, шакшылыкның үзе булган дуңгыз ите һәм Аллаһыдан башка бер нәрсәгә атап чалынган нәрсәләрдән башка хәрам булган нәрсәләр тапмыйм» (6:145).

да искә алынган айәт кәримәләрдәге чикләү «бөтен хәбаъис хәлалдер, бары тик шушы дүрт нәрсә хәрамдер», дигән мәгънәгә ия булса, айәт кәримәләрдә файда калмый, тәртип калмый. Андый чикләүнең (كُلُواْ مِن طَيِّبَاتِ مَا رَزَقْنَاكُمْ)[1], (فَكُلُواْ مِمَّا رَزَقَكُمُ اللّهُ حَلاَلًا طَيِّبًا)[1] дигән җөмләләргә һичбер мөнәсәбәте, һичнинди кагылышы булмаячак. «Хәрам нәрсәләр бары тик дүртәүдер; бөтен хәбаъис, нәҗасәт, агу-зәһәрләр хәлалдер»,– дип әйтү ул Шәригъ хәкимнең хикмәтенә, кешелек дөньясының сыйххәт-сәламәтлегенә, нәзафәтенә[2] һичнинди сурәттә туры килмәячәк. Андый дәгъва Коръән кәримнең: (وَيُحَرِّمُ عَلَيْهِمُ الْخَبَآئِثَ)[3] – (وَلاَ تَتَبَدَّلُواْ الْخَبِيثَ بِالطَّيِّبِ)[4] – (مَّا كَانَ اللّهُ لِيَذَرَ الْمُؤْمِنِينَ عَلَى مَا أَنتُمْ عَلَيْهِ حَتَّىَ يَمِيزَ الْخَبِيثَ مِنَ الطَّيِّبِ)[5], дигән айәт кәримәләренә дә һәрьяклап каршы киләчәк.

Иң бөек гыйлем ияләренең каләме белән язылган һәммә тәфсирләрне, бөтен мәзһәбләрнең карашларына тәмамы белән кушылган фәкыйһларның, мөхәддисләрнең тырышлыгы белән язылган фикъһы китапларын кеше диккать белән укыса, чикләү айәт кәримәләре хакында шушы кечкенә китапның берничә сәхифәсендә язылган бәяннның кыйммәте бераз гына булса да күз алдына китерелә алыр булса кирәк. Әлеге өч-дүрт юлны укучыларның диккатьләрен, кызыксынуларын җәлеп итү өмете белән яздым.

Коръән кәримдә хәрам тәгамнәр бәян ителгән һәр очракта изтыйрарга, ягъни мәҗбүр ителүгә, чарасыз калуга кагылышлы хөкемнәр дә хәбәр ителгән:

1) (إِنَّمَا حَرَّمَ عَلَيْكُمُ الْمَيْتَةَ وَالدَّمَ وَلَحْمَ الْخِنزِيرِ وَمَا أُهِلَّ بِهِ لِغَيْرِ اللّهِ فَمَنِ اضْطُرَّ غَيْرَ بَاغٍ وَلاَ عَادٍ فَلا إِثْمَ عَلَيْهِ إِنَّ اللّهَ غَفُورٌ رَّحِيمٌ) (әл-Бәкара сурәсе)[6].

[1] «Аллаһ сезгә хәлал вә яхшы нәрсәләр буларак ризык итеп биргән нәрсәләр белән тукланыгыз» (16:114).

[2] нәзафәт – пакьлек, сафлык, арулык.

[3] «сезнең өчен шакшыларны хәрам кыйла» (6:157).

[4] «яхшыны шакшыга алмаштырмагыз» (4:2).

[5] «Аллаһ яхшыны шакшыдан аерганчыга кадәр мөэминнәрне сезнең халәттә калдыручы түгел» (3:179).

[6] «Чынлыкта, Ул сезнең өчен үләксәне, канны, дуңгыз итен һәм дә Аллаһыдан башка бер нәрсәгә атап чалынганнарны хәрам кыйлды. Ә инде кем дә кем чарасызлыктан, әмма буйсынмау күрсәт-

2) (فَمَنِ اضْطُرَّ فِي مَخْمَصَةٍ غَيْرَ مُتَجَانِفٍ لِّإِثْمٍ فَإِنَّ اللّهَ غَفُورٌ رَّحِيمٌ) (әл-Маъидә сүрәсе)[1].

3) (وَمَا لَكُمْ أَلاَّ تَأْكُلُواْ مِمَّا ذُكِرَ اسْمُ اللّهِ عَلَيْهِ وَقَدْ فَصَّلَ لَكُم مَّا حَرَّمَ عَلَيْكُمْ) (әл-Әнгам, 119) [2].

4) (قُل لاَّ أَجِدُ فِي مَا أُوْحِيَ إِلَيَّ مُحَرَّمًا عَلَى طَاعِمٍ يَطْعَمُهُ إِلاَّ أَن يَكُونَ مَيْتَةً أَوْ دَمًا مَّسْفُوحًا أَوْ لَحْمَ خِنزِيرٍ فَإِنَّهُ رِجْسٌ أَوْ فِسْقًا أُهِلَّ لِغَيْرِ اللّهِ بِهِ فَمَنِ اضْطُرَّ غَيْرَ بَاغٍ وَلاَ عَادٍ فَإِنَّ رَبَّكَ غَفُورٌ رَّحِيمٌ) (әл-Әнгам сүрәсе)[3].

5) (إِنَّمَا حَرَّمَ عَلَيْكُمُ الْمَيْتَةَ وَالْدَّمَ وَلَحْمَ الْخَنزِيرِ وَمَا أُهِلَّ لِغَيْرِ اللّهِ بِهِ فَمَنِ اضْطُرَّ غَيْرَ بَاغٍ وَلاَ عَادٍ فَإِنَّ اللّهَ غَفُورٌ رَّحِيمٌ) (ән-Нәхел сүрәсе)[4].

Шушы биш айәт кәримәдә хәрам тәгамнәр бәян ителгәннән соң һәрвакыт мәҗбүр ителү, чарасыз калу (*изтыйрар*) очраклары да, шул изтыйрарның хөкеме дә бәян кыйлынган.

Изтыйрар нәрсә ул? Изтыйрар – ул хәлал ашамлык, хәлал эчемлек булмаган чакларда ачлыкның, хәлсезләнүнең басымы йөзеннән, яки өстенлек алачагы, бернигә дә карамастан үзенә буйсындырачагы мәгълүм булган бер көчнең яки шартның мәҗбүр итүенән гыйбарәттер. Изтыйрар сәгатьләрендә, мәҗбүр булу вакытларында тыелган, ясакланган нәрсәләр

мичә, хәттин ашмыйча шуңа мәҗбүр ителсә, аның өстендә гөнаһ юк. Аллаһ мәрхәмәтле кичерүчедер ләбаса! « (2:173).

[1] «Кем дә кем ачлыктан, гөнаһ кыйлуга авышырга теләмичә, моңа мәҗбүр булса, Аллаһ мәрхәмәтле кичерүчедер лә!» (5:3).

[2] «Ни булды сезгә? Аллаһ… сезгә нинди нәрсәләрне хәрам иткәнен тәфсилләп аңлатып биргәннән соң да Аның исеме әйтелеп чалынган мал-туар итен күрә торып ашамыйсыз! « (6:119).

[3] «Миңа иңдерелгән вәхийдә ашаучы өчен аның ашый торган тәгамнары арасында мин үләксә, агызып алынган кан, шакшылыкның үзе булган дуңгыз ите һәм Аллаһыдан башка бер нәрсәгә атап чалынган нәрсәләрдән башка хәрам булган нәрсәләр тапмыйм. Ә инде кем дә кем чарасызлыктан, әмма буйсынмау күрсәтмичә, хәттин ашмыйча шуңа мәҗбүр ителсә, синең Раббың мәрхәмәтле кичерүчедер ләбаса!» (6:145).

[4] «Чынлыкта, Ул сезнең өчен үләксәне, канны, дуңгыз итен һәм дә Аллаһыдан башка бер нәрсәгә атап чалынганнарны хәрам кыйлды. Ә инде кем дә кем чарасызлыктан, буйсынмау йөзеннән булмыйча һәм хәттин ашмыйча шуңа мәҗбүр ителсә, Аллаһ мәрхәмәтле кичерүчедер ләбаса!» (16:115).

(*хүрмәт*) калмый; хәрамнең хәрамлеге юкка чыга. «Кавагыйд фикъһия»дә бәян ителгән 21–22 нче кагыйдәләрдә әлеге мәсьәлә ачыкланып, аңлатылып бирелде. Фәкыйһлар бу кагыйдәне: «зарурәт хәрам булган нәрсәләрне мөбах итә[1]», дигән гыйбарә белән белдергән булсалар да, мин «Кавагыйд фикъһия»дә: «зарурәт сәгатьләрендә хүрмәт калмый», дигән билгеләмәне сайладым.

Фәкыйһларның гыйбарәсендә зарурәт сәгатьләрендә хүрмәтнең мәңге үзгәрешсезлеге гамәлдән чыгарылып, хүрмәтнең юкка чыгуына дәлиллек итә ала торган билгеләмә-фәлән юк. Ләкин, зарурәт сәгатьләрендә мөбахлык, ягъни Шәригънең рөхсәте, йомшаклык кыйлуы, ташлама ясавы (*мөсәгадәсе*) никадәр әһәмиятле булса, хүрмәтнең мәңге үзгәрешсез булмавы да шул кадәр үк мөһим.

Зарурәт сәгатьләрендә хүрмәт, әлбәттә, юкка чыга. Чөнки 3 нче айәт кәримәдә: (وَقَدْ فَصَّلَ لَكُم مَّا حَرَّمَ عَلَيْكُمْ إِلاَّ مَا اضْطُرِرْتُمْ إِلَيْهِ)»[2], дигән җөмләдәге искәрмә – ул тәфсилләп аңлатылган нәрсәләрдән искәрмә түгел, ә бәлки, хәрам кыйлынган нәрсәләрдән искәрмәдер. Тәфсилләп аңлатылган нәрсәләрдән искәрмә ясау ул – бәян юклыгы аркасында, ягъни ул хакта аңлатма булмавы сәбәпле, файдасыз була. Ә инде искәрмә хәрам кыйлынган нәрсәләрдән ясалган искәрмә булса, ул чакта айәт кәримә чарасызлык сәгатьләрендә хүрмәтнең юкка чыгуына дәлиллек итә.

Зарурәт сәгатьләрендә хүрмәтнең юкка чыгуы Шәригъның хөкеменә күбрәк туры килә. Айәт кәримәләрнең: (غَفُورٌ رَّحِيمٌ)[3], дигән өлешләре дә хүрмәтнең юкка чыгуына дәлиллек итәләр. Чөнки, кирәге кадәрен ашауны рөхсәт итүдә асыл мәгънә мәрхәмәт булса, мәрхәмәтнең кямиллеге хүрмәтнең юкка чыгуы белән була. Биредә кичерү – ул кирәге кадәр ашауның гөнаһын кичерү мәгънәсендә була алмый, чөнки биредә гө-

[1] мөбах итә – яраклы итә.

[2] «…чарасыз калган очракларыгызны искә алмаганда, Аллаһ сезгә нинди нәрсәләрне хәрам иткәнен тәфсилләп аңлатып биргәннән соң…» (6:119).

[3] мәрхәмәтле кичерүче

наһ юклыгы (فَلا إِثْمَ عَلَيْهِ)[1] дигән җөмлә белән катгый рәвештә белдерелгән. Бәлки, ачлык сәгатьләрендә кирәгеннән артык ашауның, гадәттә, ихтимал булуына күрә, аять кәримәдә Аллаһның кичерү сыйфаты Аның чарасыз калган кешегә җиңеллек кыйлуы аша белдерелгән булса кирәк.

Бәндә чарасыз калган вакытта хәрамнең хүрмәте белән бергә аңа хас булган начарлык та юкка чыга. Ягъни, хәрам тәгам ашарга гадәтләнгән кешенең бәдәненә ул хәрам нәрсәләр зарар китерә алса да, хәрам тәгамләрне чарасыз калган вакытта хаҗәткә күрә кирәк кадәр генә ашау кешенең бәдәненә зарар бирми. Ачлык сәгатьләрендә табигатьтә саклану куәте арткан була. Хәрам тәгамда бер начарлык булса, шул саклану куәте ул начарлыкны юкка чыгара. Шуңа күрә булса кирәк, изтыйрар хөкемнәре бәян ителгән һәр очракта гафу кыйлу, мәрхәмәт кыйлу сыйфатлары зикер кыйлынган. Гөнаһларны гафу итү булса, начарлыкларны юкка чыгару, әлбәттә, гафу итү була, әлбәттә, мәрхәмәт була.

Чарасызлык очракларына караган бу хөкемнәрендә бөтен фикъһы мәзһәбләре иттифак иткән[2] булсалар да, (فَمَنِ اضْطُرَّ غَيْرَ بَاغٍ وَلَا عَادٍ)[3] дигән аять кәримәләрнең тәфсирендә фикъһы мәзһәбләре үзара килешүгә ирешә алмаганнар.

Маликиләрнең, шәфигыйларның, хәнбәлиләрең мәзһәбләренә күрә, (فَمَنِ اضْطُرَّ غَيْرَ بَاغٍ وَلاَ عَادٍ)[4], дигән җөмлә аять кәримәдә мәзкүр[5] фигыльдән ясалган хәл булып, чарасыз калу очракларын чикләүче шарт вазифасын башкара. Шәригать тарафыннан рөхсәт ителгән нәрсәләргә сәбәп ителгән чарасызлык очраклары гомуми түгел, бәлки буйсынмаучы булмау, чаманы белү кебек шартлар белән чикләнгән. Күрә торып буйсынмаучы яки чаманы белмәүче бер кеше чарасызлыкта

[1] «аның өстендә гөнаһ юк» (2:173).

[2] иттифак итү – берләшү, бер фикердә булу, кушылу.

[3] «Ә инде берәү буйсынмау һәм гадәткә кертү йөзеннән түгел, бәлки чарасызлыктан мәҗбүр булса…» (Коръән, 2:173; 6:145; 16:115).

[4] «…буйсынмау һәм гадәткә кертү йөзеннән түгел…» (Коръән, 2:173; 6:145; 16:115).

[5] мәзкүр – искә алынган.

калса, чарасыз калу шәригать тарафыннан рөхсәт ителгән нәрсәләрнең гамәлгә ашырылуына сәбәб була ала. Әмма берәү канунны бозу мәгънәсендә бунт, фетнә, гыйсьян кыйлучы булса, яки башкаларның хокукларына орыну мәгънәсендә бер явыз булса, бу очракларда аның чарасыз хәлдә калуы шәригать тарафыннан рөхсәт ителгән нәрсәләрнең берсенә дә сәбәп була алмый.

Рөхсәт – ул зур игелеклелек, гүзәл нигъмәт. Бунт кебек, гыйсьян кебек буйсынмау галәмәтләрен зур игелеклелеккә, гүзәл нигъмәтләргә сәбәп итү Шәригъ хәкимнең хөкеменә мөнасыйп түгел. Шуңа күрә, бунт, фетнә, чуалыш кыйлучыларның, юлбасар һәм баскыннарның сәфәрләре дә, чарасыз калулары да, шәригать тарафыннан рөхсәт ителгән нәрсәләрнең һичберенә сәбәп була алмый. Фетнәче, бунт кубаручы сәфәрдә намазны кыскарта алмый, уразаны өзеп ифтар кыйла алмый; чарасыз калса әгәр, хәрам ризыклар ашый алмый.

Берәүнең сәфәре гыйсьян сәфәре булса, яки ул сәфәр мәкруһ булган бер максат өчен башлануы сәбәпле үзе дә мәкруһ булса, яки акыл белән кабул ителерлек бер максаты булмавы сәбәпле күңел ачу, кәеф-сафа коруга кайтып калса, андый сәфәр шәригать тарафыннан рөхсәт ителгән нәрсәләргә сәбәп була алмый, шәригать хөкемнәренең үтәлмәве өчен гозер вә сылтау була алмый. Искә алынган өч мәзһәб бу мәсьәләдә әнә шулай иттифак иткәннәр.

Әмма хәнәфиләрнең мәзһәбенә күрә, (غَيْرَ بَاغٍ وَلاَ عَادٍ)[1] дигән җөмлә айәт кәримәдә мәзкүр фигыльдән ясалган хәл булмыйча, бәлки урын шарты белән мәгълүм булган бер фигыльдән ясалган хәлдер: (فَمَنِ اضْطُرَّ فأكل غَيْرَ بَاغٍ وَلَا عَادٍ)[2] дигән җөмләдәге кебек. Бу тәкъдирдә чарасызлык гомуми рәвештә күздә тотыла, шуңа күрә фетнәче-бунтовщикларның, гыйсьянчыларның чарасызлыклары да айәт кәримәләрнең гомумиләштерүенә, әлбәттә, керә. Хүрмәтне юкка чыгару хакында (وَقَدْ فَصَّلَ

[1] «…буйсынмау һәм гадәткә кертү йөзеннән түгел…» (Коръән, 2:173; 6:145; 16:115).

[2] тәрҗемәсе: «Ә инде берәү чарасызлыктан мәҗбүр булса, ул чакта аша, әгәр буйсынмау һәм гадәткә кертү йөзеннән булмаса».

(لَكُم مَّا حَرَّمَ عَلَيْكُمْ إِلَّا مَا اضْطُرِرْتُمْ إِلَيْهِ)[1] дигән айәт кәримәдә чарасызлык гомуми хәл буларак искә алынган. Шуңа күрә, шәригать тарафыннан рөхсәт ителгән нәрсәләрнең гамәлгә ашырылуы өчен чарасызлык, һәрхәлдә, сәбәп була, һәрхәлдә, гозер була.

(إِلَّا مَا اضْطُرِرْتُمْ إِلَيْهِ)[2] дигән җөмләдә гомумиләштерү хәнәфиләрнең карашын раслый ала. Ләкин, айәт кәримәдә фаразлау кебек, искәрмә ясау кебек хәйләләргә булган ихтыяҗ хәнәфиләр карашының берникадәр җитешсезлеккә ия булуын күрсәтә. Чөнки төзек, дөрес вә аңлаешлы сөйләмнең асыл нигезе вә билгесе булып укучының ул сөйләмне аңлар өчен фараз кыйлуга, аңлашылып бетмәгән нәрсәне җиренә җиткерер өчен «дөресләүгә» мохтаҗ булмавы кебек үзенчәлекләр тора.

Шушы ике караш, ягъни өч мәзһәбнең уртак карашы белән хәнәфиләрнең махсус карашы, усуле фикыһның кагыйдәләренә күрә, әлбәттә, мөгътәбәрдер, ягъни кабул ителергә лаек. Һәркем ихтыярына күрә тегесен яки монысын сайлый ала. Ул мәзһәбләрнең дәлилләренә әһәмият бирүче бер фәкыйһ та шул ике карашның берсенә өстенлек бирә ала.

Хәнәфиләрнең карашына түбәндәге сәбәпләр аркасында өстенлек бирергә мөмкин: 1) Баш күтәрү, ул, әйтик, гыйсьяндыр. Гыйсьян гыйсьянны вазифа итә алмый. Баш күтәрү яки бунт вакытында кеше чарасыз калса, җанны саклап калу өчен ул, әлбәттә, хәрам булган ашамлыкларны да ашый ала. Юкса, кеше үзен үзе харап иткән була. 2) Һәлакәткә китерүче сәбәпләргә каршылык күрсәтү, һәрхәлдә, ваҗибтыр. Чуалыш, бунт күтәргән кешенең өстенә, мәсәлән, йә арыслан, йә дошман һөҗүм итсә, аңа каршы тору, әлбәттә, ваҗиб була. Ачлык, сусызлык бәласе белән дә шулай. Гыйсьянчы гыйсьян кыйлганда ачлыктан чарасыз калса, ашау, әлбәттә, ваҗиб була. 3) Бунтчы, гыйсьянчы адәм ач булып чарасыз калган очракта, берәү аңа ашарга бирсә, аны кабул итеп алу рөхсәт ителә генә түгел, хәтта ки ваҗиб була. Кеше белән кешенең мөгамәләсе

[1] «чарасыз калган очракларыгызны искә алмаганда, сезгә нинди нәрсәләрне хәрам иткәнен тәфсилләп аңлатып биргәннән соң» (6:119).

[2] «Чарасыз калган очракларыгызны искә алмаганда…» (6:119).

шундый булса, бунт күтәрүче булса да, гыйсьянчы булса да, ачлыкка тарыган кешеләргә Шәригъның ташламасы ярдәме тагын да зуррак булырга тиеш. Ачлык сәбәпле чарасыз калган кешеләрнең һәрберенә, һәрхәлдә, Шәригъ кәрим хәрам булган ризыкларның һәрберене, әлбәттә, мөбах итә. Гыйсьян Шәригънең ташламасына комачау була алмый.

Өч мәзһәбнең карашын сайлап алуны да мөмкин кыйлган сәбәпләр бар: 1) Ачлыкка тарыган кешеләргә ташлама ясау, һәрхәлдә, әлбәттә, шәригатькә туры килә. Ләкин ач калган гыйсьянчыларга ташлама ясауның ике юлы бар. Берсе – хәрам ризыкларны хәлал иту юлы белән; икенчесе – андый кешене итәгать даирәсенә, буйсынуга дәгъвәт итеп, аңа хәлал тәгамнәрне бирү юлы белән. Шәригънең хөкеменә, дәүләтнең мәсълихәтенә бу соңгы юл күбрәк туры килә. Чөнки әүвәлге юл белән ташлама ясау гыйсьянны кабул итү, тану кебек бер нәрсә була. Бу исә Шәригънең хикмәтенә мөнасыйп булмый.

2) Кеше үләксә кебек хәрам кыйлынган тәгамнәрдән, әлбәттә, нәфрәтләнә. Ачлык аркасында кирәк кадәрен ашый алса да, кирәгеннән күбрәкне ашамый яки ашый алмый. Шуңа күрә, (فأكل غَيْرَ بَاغٍ وَلاَ عَادٍ)[1], дигән җөмлә файдасыз кала. Чөнки үләксә кебек нәрсәләрне ашауда тәгадди итмәк гадәттә мөмкин түгелдер. Ягъни, (غَيْرَ بَاغٍ وَلاَ عَادٍ)[2] дигән чикләү, хәнәфиләрнең карашына күрә, файдасыз була.

3) Коръән кәримдә (غَيْرَ بَاغٍ وَلاَ عَادٍ)[3] дигән җөмлә – мәзкүр фигыльдән ясалган хәлдер. Җөмлә төзелеше кагыйдәләренә күрә, хәл белән эшне башкаручының кушылуы, әлбәттә, шарттыр. Әгәр дә: (غَيْرَ بَاغٍ وَلاَ عَادٍ)[4], дигән гыйбарә ашау ягына үзгәртелсә, аларның кушылган булырга тиешлеге юкка чыга. Чөнки кирәк кадәр ашаганнан соң, кешедә чарасызлык кал-

[1] тәрҗемәсе: «ул чакта ашасын, әгәр буйсынмау һәм гадәткә кертү йөзеннән булмаса».

[2] «..буйсынмау һәм гадәткә кертү йөзеннән түгел…» (Коръән, 2:173; шулай ук: 6:145; 16:115).

[3] «…буйсынмау һәм гадәткә кертү йөзеннән түгел…» (Коръән, 2:173; шулай ук: 6:145; 16:115).

[4] «…буйсынмау һәм гадәткә кертү йөзеннән түгел…» (Коръән, 2:173; шулай ук: 6:145; 16:115).

мый. Хәл – эшне башкаручыны сызып аткандай була. Ягъни, хәнәфиләрнең җөмлә төзелешенең әлеге мөһим кагыйдәсенә карашы дөрес түгел.

4) Югарыда китерелгән икенче айәт кәримәдә, ягъни (فَمَنِ اضْطُرَّ فِي مَخْمَصَةٍ غَيْرَ مُتَجَانِفٍ لِّإِثْمٍ فَإِنَّ اللَّهَ غَفُورٌ رَّحِيمٌ)[1] дигән айәт кәримәдә гөнаһларның һичберенә авышуның булмавы шарт ителгән. Шуңа күрә, бунтовщик вә гыйсьянчыларның чарасыз хәлдә калулары гозер була алмый. Юкса, Коръән кәримнең (غَيْرَ مُتَجَانِفٍ لِّإِثْمٍ)[2] дигән җөмләсе гамәлдән чыгарылырга тиеш булыр иде.

Чарасызлык очрагында фикһы мәзһәбләренең карашларын, дәлилләре белән бергә, биредә бәйнә-бәйнә күрсәттек. Һәрбер мәсьәләдә фикһы карашларын кеше, әлбәттә, ирекле сурәттә тәнкыйть күзлегеннән карап тикшерә ала. Мәзһәбләр арасындагы каршылыклы караш вә хөкемнәр аларга карап соклану, хәйран калу өчен түгел, ә бәлки фикер йөртүдә хөррият өчен, яшәеш шартларын киңәйтү өчен хезмәт итсәләр, яхшы булыр иде, мәгънәле булыр иде. Алардан файдалана алсак, мәзһәбләр арасындагы каршылыклы караш вә хөкемнәр, әлбәттә, рәхмәттер.

Исламият дөньясында ислами гыйлемнәрне терелтү, җанландыру таләп ителә икән, бүгенге көндә гамәлдә булган мәзһәбләрнең һәрберсен дини мәдрәсәләрдә укыту, әлбәттә, тиешле эш. Көнбатыш дөньясының хокук гыйлеме, иҗтимагый фәннәре арасында ислам шәригатенә дә бер бәхәссез кыйммәт бирдерү өчен, без бөтен фикһы мәзһәбләрен тулысынча барлап чыгып теркәргә, тәртипкә салырга тиешбез.

Ислам галәменең фәкыйһлары бу хакыйкатьне аңласалар, бу зарурәтне кабул итсәләр, ярар иде. Фикъһының әүвәлге мәзһәбләреннән, Көнбатышның хокук гыйлеменнән, иҗтимагый фәннәреннән гафил булсак, яки бөтен һиммәт-тырышлыгыбызны Көнбатышның хокукларына, иҗтимагый фәннәренә багышласак, ислам шәригате безнең кулыбыздан, әлбәттә, китәчәк, юкка чыгачак.

[1] «кем дә кем ачлыктан, гөнаһ кыйлуга авышырга теләмичә, моңа мәҗбүр булса, Аллаһ мәрхәмәтле кичерүчедер ләбаса! « (5:3).

[2] «гөнаһ кыйлуга авышырга теләмичә» (5:3).

Мин инкяр итмим: ислам галәмен, әлбәттә, ислях кыйлырга һәм төзекләндерергә кирәк. Ләкин, исляхатның, төзекләндерүнең иң мөһим нигезләрен үткән заманнарда эзләргә кирәк. Борынгы игелекле бабаларыбыздан безгә мирас булып калган барлык хәзинә вә җәүһәрләрне эзләп табу ул – исляхат һәм төзекләндерүнең иң беренче нигезедер.

# IV БҮЛЕК.
# Чыганаклар һәм әдәбият

# I. Чыганаклар

## 1) Муса Бигиевнең үз фамилиясе белән бастырган китаплары һәм мәкаләләре:


Бигиев, Муса. *Фәйләсүф имам кәбир Аби әл-Галә әл-Мәгарри хәзрәтләренең әл-Лүзүмийәт намында бөек әсәрендән интихабән бер биң өч йөз кадәр әдәбийат гыйльмийә тәрҗемә улынды Муса Бигиев каләмейлә*. Казан: Әхмәд әл-Исхакый нәшрияты, 1907. 208 б.

Бигиев, *Муса. Әдәбийат гарәбийә илә голүм исламийә*. Казан: «Мәгариф», 1909. 72 б.

Бигиев, Муса. Мөхәммәт Заһир әфәнде Бигиев. // Мөхәммәт Заһир Бигиев. *Мәвараэннәһердә сәйахәт. Трансоксанияйә* сәфәр. Казан: «Китап» нәшрияты, 1908. 2 б.

Бигиев, Муса. Иман хакында бер ике сүз. Әхмәд бин әл-Әмин әш-Шикыйти. *Дәлилүн сарихун фи нөзүли әл-Мәсихи*. Казан: Мәгариф көтебханәсе, 1909. 2–4 б.

Бигиев, Муса. Иң ахыр сүзем. // *Вакыт*. 1909. № 556.

Бигиев, Муса. *Диван-ы Хафиз тәрҗемәсе*. Казан: «Үрнәк» матбагасы, 1910. 145 б.

Бигиев, Муса. Шәригать исламийә хөрмәтенә бер риҗа – Ачык мәктүп // *Тәгаруфы мөслими*н. 1910. 29 октябрь. 301–302 б.

Бигиев, Муса. *Шәригать ничүн роэйәти игътибар итмеш?* Казан: Әхмәд әл-Исхакый, 1910. 110 б.

Бигиев, Муса. *Рәхмәт илаһийә борһанлары*. Оренбург: «Вакыт», 1911. 97 б.

Бигиев, Муса. *Инсанларның гакыйдә илаһийәләренә бер назар*. Оренбург: «Вакыт», 1911. 26 б.

Бигиев, Муса. Кавагыйд фикъһийә // *Шура*. 1911. № 2. 43–45 б.

Бигиев, Муса. Будущее мусульманства. (Перевод). //*Мир ислама*. Т. 2, вып. V. 1913.

Бигиев, Муса. *1917 ел 1–11 майда Москва шәһәрендә гомум Русия мөселман съезды хакында кыскача мәгълүмат*. Казан, 1917. 16 б.

Бигиев, Муса әфәнде. *Халык назарына берничә мәсьәлә*. Казан: Электро-Типография «Умид», 1912. 94 б.

Бигиев, Муса Җаруллаһ. *Шәригать исламия әлифбасы мөсабәсендә игътибар кыйлына билүр Кавагыйд фикъһийә* (әхкям шәргыйә мәҗәлләсенә мәдхәл улмак сыйфатыйлә) остаз мөхтәрәм Риза әфәнде хәзрәтләренең иршады, нәзарәте һәм заманы тәхтендә Муса Җарулла Бигиев каләмейлә тәэлиф кыйлынмышдыр. Казань: Электро-Типография «Урнэк», 1328 [1910]. 232 б.

Бигиев, Муса Җаруллаһ. *Озын көнләрдә рузә*. Казань: Электро-Типография «Умид», 1911. 208 б.

Бигиев, Муса Җаруллаһ. *Шәригать исламия әлифбасы мөсабәсендә игътибар кыйлына билүр Кавагыйд фикъһийә* (әхкям шәргыйә мәҗәлләсенә мәдхәл улмак сыйфатыйлә) остаз мөхтәрәм Риза әфәнде хәзрәтләренең иршады, нәзарәте һәм заманы тәхтендә Муса Җарулла Бигиев каләмейлә тәэлиф кыйлынмышдыр. Казань: Электро-Типография «Урнэк», 1328 [1910]. 232 б.

Җаруллаһ, Муса. *Әл-Мөвафәкать мөкаддимәсе*. Казан, 1909. 14 б.

Җаруллаһ, Муса. *Дәүләт думасында мәет якмак мәсьәләсе*. СПБ.: Тип. М-А. Максутова, 16 б.

Җаруллаһ, Муса. *Маъидә*. СПб.: Тип. М-А. Максутова. 34 б.

Җаруллаһ, Муса. *Остаз мөхтәрәм Риза әфәнде хәзрәтләренең «Дини, иҗтимагый мәсьәләләр»енә интикад мөнәсәбәтейлә (берничә) мөляхәза*. СПб.: Типография М-А. Максутова. 56 б.

Җаруллаһ, Муса. *Бөек мәүзугларда уфак фикерләр*. СПб.: Типография М-А. Максутова, 1914. 112 б.

Җаруллаһ, Муса. *Петербургда 1914 сәнә июнь 15–25-дә рәсми җәмгыять мөнәсәбәтейлә исляхат әсасләре*. Петроград, Типография М-А. Максутова, 1915. 288 б.

Җаруллаһ, Муса. *Фикъһу әл-Куръәни*. Петроград: Типография М-А.– Максутова, 1915. 32 б.

Җаруллаһ, Муса. *Зәкят*. Петроград, Типография М-А. Максутова, 1916. 96 б.

Җаруллаһ, Муса. *Хокук әсасия (124 статья). 1906 сәнә април 23-дә тәсдыйк кыйлынмыш әсас канунлар*. Петроград: Типография М-А. Максутова, 1916. 20 б.

Җаруллаһ, Муса. *Шәригать әсасләре*. Петроград: Типография М-А. Максутова, 1917. 74 б.

Җаруллаһ, Муса. *Ислам милләтләренә дини, әдәби, иҗтимагый, сәйәси мәсьәләләр тәдбирләр хакъкынд*а. Берлин, 1923. 110 б.

Җаруллаһ, Муса. *Шәригать исламийә назарында мөскират мәсьәләләре*. Истанбул: Мәхмәд бәк матбагасы, 1927. 48 б.

Җаруллаһ, Муса. *Корьән кәрим айәт кәримәләренең могъҗиз гыйбарәләренә күрә Йа́җүҗ*. Берлин, 1933. 38 б.

Җаруллаһ, Муса. *Корьән кәрим айәт кәримәләре нурлары хозурында хатун*. Берлин, 1933. 112 б.

Җаруллаһ, Муса. *Тарихның онытылмыш сәхифәләре*. Беренче халка: Солтан Газизнең шәһадәтенә асыл сәбәб нә иде? Берлин, 1933. 18 б.

Җаруллаһ, Муса. Әл-Вәшигату фи нәкъди гакаъиди әш-шигати. Каһирә: Матбагату әл-Киляни, 1982. 238 с.

Ибн Фатыйма. *Низаму әт-тәкъвими фи әл-ислами*. Каһира: Матбагату әс-сәгадәти, 1935. 28 с.

Рустуфдони, Муса Җарулла. *Таъриху әл-Куръәни вә әл-мәсахифи*. СПб.: Тип.– Лит. И. Бораганского и К°, [1905]. 38 с.

Рустуфдуни, Муса Җаруллаһ. *Китабу гакыйләти атраби әл-касаъиди фи әсна әл-макасыйд*. Казань: Типография Т-го Д-ма «Братья каримовы», 1908. 72 б.

Рустуфдуни, Муса Җаруллаһ. Китабу таһарати әл-гарәби. Казан, 1326 һ. [м. 1908]. 48 б.

Рустуфдуни, Муса бин Җаруллаһ. *Таййибату ән-нәшри фи әл-гашри*. Казан: «Өмид», 1912. 308 б.

Musa Cârullah. Surelerin nüzul tarihi itibariyle tertibi. *Yeni Selâmet*. C. IV, Sayı 19–87. 18 мая 1949. S. 4, 16.

## 2) Муса Бигиев әзерләп чыгарган башка авторларның китаплары:

Бигиев, Мөхәммәт-Заһир. *Мәвараэннәһердә сәйахәт. Трансоксаниййә сәфәр*. Казан: «Китап» нәшрияты, 1908. 108 б.

*Исляхат әсасләре*. Төз. Муса Җаруллаһ. Петроград: Тип. М-А. Максутова, 1915. 290 б.

*Китабу әл-мөвафәкати ли-имами әл-хафизи әл-мөфассири әл-фәкыйһи әл-усулийи әш-шәйхи Аби Исхак Ибраһим ибни Муса әш-Шатыби радыйа Аллаһу ганһу*. Казан: Сабах көтепханәсе, 1909. 190 б.

*Китабу әш-Шатыбийәти ли-имами әл-хуффаз әл-әгълам әл-устаз Аби Мүхәммәд әл-Касим әш-Шатыби радыя Аллаһу ганһу*. Казан: Лито-Типография Торговаго Дома «Братья Каримовы», 1907. 88 б.

*Назымәтү әз-зүһри* ли-имами Аби Мүхәммәди әл-Касими бни Фирруһи әш-Шатыбийи радыйа Аллаһу ганһу. Оренбург: Тип. Газ. «Вактъ», 1910. 112 б.

*Тәсъхыйхы рәсме хатты Коръән*. Казан: «Бәйанел-хак» идарәсе, 1909. 94 б.

## 3) Муса Бигиевнең куен дәфтәрләре:

A3851–4. Кулъязма. Milli Kütüphane. Ankara.

A5924. Кулъязма. Milli Kütüphane. Ankara.

## 4) Иске татар, татар һәм рус телендә чыганаклар:

Айда, Адиле. Садри Максуди Арсал / пер. с тур. В. Б. Феоновой; науч. ред., прим. и послесл. С. М. Исхакова. М., 1996. 359 с.

Айни, Садриддин. Бухара: (Воспоминания). В 2-х кн. Кн. 2 (Пер. с тадж. С. Бородина; Отв. ред и авт. послесловия К. С. Айни). Душанбе: Ирфон, 1981. кн. 1. 260 с.

Әл-Кәмали, Зыяэтдин. *Дини тәдбирләр*. Исляхат диния көтебханәсендән беренче китаб. Уфа «Шәрык» матбагасы бәрадәран Кәримовларның, 1913. 88 б.

Әл-Мөвафәкать // *Шура*. 1909. № 10. 315 б.

Әһле исламның берлеге хакъкында маддәләр // *Сәбилерришад*. 1924. 6 Mart. Т. 23. № 591. 303 б.

Әһле исламның тәгарруфы хакъкында маддәләр (Муса Җаруллаһ әфәнденең большевикләрчә мөҗиб-е тәукыйфы олан китабдан) // *Сәбилерришад*. 1924. 6 Mart. Т. 23. № 591. 303 б.

Әш-Шинкыйти, Әхмәд бин әл-Әмин. *Дәлилүн сарихун фи нүзүли әл-Мәсихи*. Казан: Мәгариф көтебханәсе, 1909. 16 б.

Бартольд, В. Два течения. Современные улемы // *Мир Ислама*. 1913. Т. 2, вып. 1. СПб, С. 41–42.

Баруди, Галимҗан. *Хатирә дәфтәре: 1920 елның 12 июненнән алып сентябрь ахырына кадәр* / Басмага әзерләүче А. Гайнетдинов. Казан: ТР ФА Ш. Мәрҗани исемендәге Тарих институты, 2017. 236 б.

Бәкер, Кәбир. *Тукай Петербургта*. Оренбург, 1914.

Гаспринский И. Тарих-ы әдъйан вә исабәт // *Тәрҗеман*. 1909. 25 декабрь. № 52.

Голәма иттифакы. Беренче нәдвәсе. Төз. Ш. Шәрәф. Казань: типолитография Т.Д. «Бр. Каримовы», 1917. 58 б.

Гомуми әсасләр: Муса Җаруллаһ әфәнденең большевикларча мөҗибе тәүкыйфы олан китабындан // *Сәбилерррищад*. 1924. 3 январь. Т. 23. № 582. 151 б.

Исхаков, М. Г. *Әсәрләр*: 15 т. Т. 14: хатлар һәм автобиографик язмалар [томны төз., текст. Һәм аңлатмалар. әзер., кереш сүз авт. Ф. Фәйзуллина]. Казан: Татар.кит. нәшр., 2013. 479 б.

Коммунизм галәйһендә Муса Җаруллаһ әфәнденең нәшер иттеки китаб // *Сәбилерррищад*. 1923. 27 декабрь. Т. 23, № 581. 132–137 б.

Китабу әл-Моваттаъ // *Шура*. 1909. № 13.

Әхмәт Һади Максудов. Уфак фикерләр // *Йолдыз*. 1914. № 1224. 9 июль.

Мөҗтәһидләрнең мөҗтәһиде // *Мәхфил*. 1921. Т. 1. № 14. Август-сентябрь, 22–23 б.

Мөтәвәлиләр мәҗлесе // *Вакыт*. 1909. № 559.

Муса әфәнденең дәгъвәте хакында // *Вакыт*. 1909. № 554.

Муса Җаруллаһ әфәнденең тәукыйфе // *Сәбилерррищад*. 1923. 20 декабрь. Т. 23. № 580. 128 б.

Сабри, Мостафа. *Дини мөҗәддидләр йахуд «Төркия ичүн нәҗат вә игътиля йуллары»нда бер раһбәр*. Шаһзадә башы: Уфак матбагасы. 1338–1340. 374 б.

Салим. Обзор мусульманской жизни // *Мир Ислама*. 1913. Т. 2, вып. 2. С. 126–128.

Тәкъриз // *Шура*. 1909. № 3. 88 б.

Тәсъхыйхы рәсме хатты Коръән. Казан: «Бәйанел-хак» идарәсе, 1909. 94 б.

Тоган, Заки Валиди. *Воспоминания*: Книга I. Уфа: Башкирское изд-во «Китап», 1994. 400 с.

Фәхретдин, Р. Ырынбург шәһәрендән Бөгелмә өязендән «Әлмәт» карьясендән // *Вакыт*. 1909. № 554.

Фәхретдин, Ризаэтдин бин-е. *Дини вә иҗтимагый мәсьәләләр*. Оренбург: «Вакыт», 1914. 208 б.

Халык назарына берничә мәсьәлә // *Шура*. 1912. № 24.

Һади. Тик тора алмыйм // *Шура*. 1909. № 24. 756–758 б.

Шәкки // *Шура*. 1910. № 2.

Шәрәф Б. Мәдәнилеккә имтихан. // *Вакыт*. 1909. № 558.

ЦА ФСБ РФ. Архивно-следственное Дело № Р-46032.

## 5) Чит телләрдәге чыганаклар:

Battal-Taymas, A. *Musa Carullah Bigi. Kişiliği, fikir hayatı ve eserleri*. Kazanlı Türk Meşhurlarından II. İstanbul, 1958. 64 s.

Battal-Taymas, A. *Alimcan Barudî. Kişiliği, fikir hayatı, içtimai-kültürel emekleri ve iki ek*. Kazanlı Türk Meşhurlarından III. İstanbul: M. Sıralar Matbaası, 1958. 80 s.

Battal-Taymas, A. Üstad Musa Carullah Üzerine Notlar. *Alimcan Barudî. Kişiliği, fikir hayatı, içtimai-kültürel emekleri ve iki ek*. Kazanlı Türk Meşhurlarından III. İstanbul: M. Sıralar Matbaası, 1958. S. 62–74.

Büyük Üstad Musa Cârullah 25 Ekımde Allahın Rahmetine Kavuştu. *Yeni Selâmet*. 1949. Cilt IV. Sayı 36–104. S.10–11.

Cârullah, Musa. Surelerin nüzul tarihi itibariyle tertibi. *Yeni Selâmet*. C. IV, Sayı 19–87. 18 Mayıs, 1949. S. 4, 16.

Cevdet, Mahmud. Büyük Türk Bilgini Musa Carullah ile Bir Karşılaşma. *Doğan Güneş*. 17 Eylül 1947. 5. Sayı, 76. Sayfa.

Cevdet, Mahmud. Hoş geldiniz. *Doğan Güneş*. 17 Eylül 1947. 5. Sayı, 72. Sayfa.

Doğrul, Ömer Rıza. Musa Carullah. *Yeni Selâmet*. 26 Eylül 1947.

Doğrul, Ömer Rıza. *Yeni Selâmet*. T. IV, Sayı 12–80. 30 март 1949. S. 4.

Emir oğlu, Şir. Allâme Musa Carullah vefat etti. *Sebilürreşad*. 1949. Cilt: III. Sayı: 65. S. 236.

Filozof Musa Carullah Bigi. *Uzun Günlerde Oruç. İctihad Kitabı* / Eseri sadeleştirerek dipnotlarla işleyen Yusuf Uralgiray. Ankara, 1975. 242 s.

Jeffery A. *Materials for the History of the Text of the Qur'an: The Old Codices*. Leiden: E. J. Brill. 1937. 630 p.

Musa Cârullah. Başbakandan Bir Rica. *Yeni Selâmet*, 29 Haziran 1949. Cilt IV. Sayı 25–93. S. 3,13.

Musa Cârullah'la Mısırda bir mülâkat. *Yeni Selâmet*. 3 Ağustos 1949. Cilt IV. Sayı 24–98. S.6–7.

*T.B.M.M. Zabıt Ceridesi*. Cilt 18. 1 Mart 1338 tarihli Birinci İçtimadan 4 Nisan 1338 tarihli Yirminci İçtimaa kadar. Ankara: T.B.M.M. Matbaası, 1959. S. 479.

*T.B.M.M. Zabıt Ceridesi*. Cilt 19. 6 Nisan 1338 tarihli Yirmi Birinci İçtimadan 6 Mayıs 1338 tarihli Kırkıncı İçtimaa kadar. Ankara: T.B.M.M. Matbaası, 1959.

Togan, Z. V. Büyük Âlim Musa Cârullah Reformatör müdür? *Tasvir*. 23 Eylül 1947.

Togan, Zeki Velidi. Musa Cârullah Begi'nin Hayatı ve Eserleri. *Selâmet*. Sayı: 5. Cilt 105. Sayı (23 Kasım 1949). 2, 5–7, 16 s.

Uralgiray, Yusuf. Önsöz. Filozof Musa Carullah Bigi. *Uzun Günlerde Oruç. İctihad Kitabı* / Eseri sadeleştirerek dipnotlarla işleyen Yusuf Uralgiray. Ankara, 1975. 242 s. / Y. Uralgiray. S. XII–XXVI.

Uralgiray, Yusuf. Üstâdimiz Musa Cârullah'ın «Finlandiya Cemaat İslâmiyesi» başkanı hafiz imam Veli Ahmed Hakîm hazretlerine muhtelif tarihlerde yazdığı mektuplar. Filozof Musa Carullah Bigi. *Uzun Günlerde Oruç. İctihad Kitabı* / Eseri sadeleştirerek dipnotlarla işleyen Yusuf Uralgiray. Ankara, 1975. / Y. Uralgiray. S. 1–22.

Ustat Musa Carullah Bıgı Hz. *Millet*. 18 Kasım 1948. Sayı 145. Sene: 3.

*1906 сәнә 16–21 августда иҗтимаг итмеш Русия мөселманларының нәдвәсе*. Матбага-и Кәримия Казанда 1906 сәнә. Казань: Типо-Литография Торговаго Дома «Братья Каримовы», 1906 171 б.

## II. Әдәбият

### 1) Татар һәм рус телләрендә:

Аксой, Неслихан Арул. История моей семьи. Фаузия Габдерашит // Ибрагимова Ф. Мастер кулинарии: подарок для дам = Аш остасы: ханымнарга һәдия. Казань: Изд-во «Познание» Казанского инновационного ун-та, 2017. 234 с. (на рус. и тат. яз.)

Батулла, Р. Дин галименең сурәтенә кайбер шәрехләр // *Муса Бигиев: мирас һәм хәзерге заман. Халыкара фәнни конференция материаллары*. Казан, декабрь, 1999 ел. Казан: Гөлстан, 2000. 175–184 б.

Бигиева-Таһирҗанова Фатыйма. Әтием хакында хатирәләр // Муса Бигиев: мирас һәм хәзерге заман. Мәкаләләр җыентыгы. Казан: Гөлстан, 2000. 172–174 б.

Исаев, Габделбари хәзрәт Низаметдин улы. *Коръән Кәрим тәрҗемәсе* / Фәнни мөхәррире Ә.К. Бостанов. Казан: Изд-кий дом «Казанская недвижимость», 2018. 552 б.

*Муса Бигиев: мирас һәм хәзерге заман. Халыкара фәнни конференция материаллары*. Казан, декабрь, 1999 ел. Казан: Гөлстан, 2000. 188 б.

Рәхимова, Асия. «Шу мәктүбем сүзләре сезә әманәтдер» // Гасырлар авазы / Эхо веков. 1996. № 1/2. 200–205 б.

Тагирджанова А.Н. Книга о Мусе-эфенди, его времени и современниках. Казань, 2010. 576 с.

### 2) Чит телләрдә:

Görmez M. Musa Carullah Bigiyef. Ankara: Türkiye Diyanet Vakfı Yayınları: 1994. 228 s.

Balcıoğlu, Tahir Harimi. Büyük islam âlimi Musa Carullahı nasıl tanıdım // *Sebilürreşad*. 1949. Cilt: III; Sayı: 65. Sayfa: 237–238.

Hammond, Kelly. China's Muslims and Japan's Empire: Centering Islam in World War II. The University of North Carolina Press; Illustrated edition (November 16, 2020). 314 p.

Kanlıdere, Ahmet. Kadimle Cedit Arasında Musa Cârullah. Hayatı / Eserleri/Fikirleri. Ankara: Dergâh Yayımları: 2005. 280 s.

Koca, Ferhat. Musa Carullah Bigiyef ve İslam Kongreleri (1926–1931). *Hitit İlahiyat Dergisi*. Haziran/June 2022. 21/1. S. 33–80.

Rubin, Barry; Schwanitz, Wolfgang G. Nazis, Islamists, and the Making of the Modern Middle East. Yale University Pres, 2014. 340 s.

Sat, Nurullah. Abdürreşid İbrahim ve Musa Carullah'ın Talebesi Toshihiko Izutsu'nun Hayatı Eserleri: Türklere ve İslam'a Bakışı. *Bilig*. 2020, № 95. 97–122 s.

Wiesenthal, Simon. Ich jagte Eichmann. S. Mohn, 1961. 254 p.

Usmanova, Larisa. The Türk-Tatar Diaspora in Northeast Asia. Transformation of Consciousness: A Historical and Sociological Account Between 1898 and the 1950s (Tokyo: Rakudasha, 2007), 367p.

## III. Автор-төзүченең Муса Бигиевкә кагылышлы хезмәтләренең исемлеге

*(1998–2022 еллар)*

**1998**

1. Хайрутдинов А. *Муса Бигиев об абсолютности Божьей милости*. Казань: Иман, 1998. 40 с.

2. Хәйретдин А. Исламият һәм хатын-кыз // *Сөенбикә*. 1998. № 7. 12–13 б., № 8. 34–35 б.

3. Хәйретдин А. Муса Бигиев һәм Корьән кәрим тәрҗемәсе // *Иман*. 1998. 21 май.

4. Хәйретдин А. Шөһрәтле дин галименең кыскача язмышы вә мәсләге // *Ислам нуры*. 1998. № 21.

5. Хәйретдин А. Тәнкыйть кенә түгел. Муса Бигиев: Исламиятне инсаннарга тәблигъ юллары // *Иман нуры*. 1998. Январь.

6. Хәйретдин А. Мәдәният дөньясы тәрәккый итмеш икән, Исламият дөньясы ни өчен инде? // *Иман нуры*. 1998. Март.

**1999**

7. Бигиев М. *Илаһи мәрхәмәтнең дәлилләре* / Төзүче, төп текстның транскрипциясе, хәзерге татар теленә тәрҗемә һәм искәрмәләр А. Г. Хәйретдинов Казан: Казан ун-ты нәшр., 1999. 196 б.

8. Хайрутдинов А. Г. *Последний татарский богослов. Жизнь и наследие Мусы Джаруллаха Бигиева*. Казань: Иман, 1999. 138 с.

9. Хайрутдинов А. Г. Муса Бигиев об абсолютности Божьей милости // *Мир Ислама*. 1999. № 1. С. 171–186.

**2000**

10. Хайрутдинов А. Г. *Наследие Муса Джаруллаха Бигиева*. Сб. документов и материалов. Ч. I. Казань: Иман, 2000. 71 с.

11. Хайрутдинов А. Г. *Наследие Муса Джаруллаха Бигиева*. Сб. документов и материалов. Ч.II. Казань: Иман, 2000. 90 с.

12. Хайрутдинов А. Г. *Наследие Муса Джаруллаха Бигиева*. Сб. документов и материалов. Ч.III. Казань: Иман, 2000. 52 с.

13. Бигиев М. Җ. *Гарәп әдәбияты һәм ислам фәннәре* / Тышлык, төзелеше, кереш мәкалә, тәрҗемә һәм искәрмәләр: Хәйретдинов А. Г. Казан: Иман, 2000. 127 б.

14. Хәйретдинов А. Г. Муса Бигиев – исламчылык идеологы // *Муса Бигиев: Мирас һәм хәзерге заман*. Халыкара фәнни конференция матер. Казан, 2000. 54–63 б.

**2001**

15. Бигиев М. Җ. «*Әл-Муәфәкать*» *мөкаддимәсе* / Татарчага тәрҗемә, кереш сүз: А. Хәйретдин. Казан: Иман, 2001. 21 б.

16. Хайрутдинов А. Последний татарский богослов // *Оазис*. 2001. № 1. С. 18–20.

17. Муса Бигиев. Почему Запад прогрессировал, а мир Ислама отстал? Из книги «Несколько вопросов вниманию народа» (Казань, 1912) Перевод со старотатарского А. Хайрутдинова // *Оазис*. 2001. № 2. С. 4–5.

**2002**

18. Хәйретдинов А. Муса Җаруллаһ Бигиев һәм фикъһы мәзһәбләре // *Сб. материалов итоговых научных конференций молодых ученых и аспирантов Института истории им. Ш. Марджани АН РТ за 2001–2002 г.* Казань: Изд-во института истории АНТ, 2002. С. 270–279.

19. Хайрутдинов А.Г. Бигиев Муса (Муса Джаруллах) // *Татарская энциклопедия*: В 5 т. / Гл. ред. М.Х. Хасанов, отв. Ред. Г.С. Сабирзянов. Казань: Институт Татарской энциклопедии АН РТ, 2002. Т. 1: А-В. С. 378.

**2003**

20. Хайрутдинов А.Г. *Наследие Мусы Джаруллаха Бигиева*. Сб. документов и материалов. Вып. IV. Казань: Изд-во Института истории АНТ, 2003. 72 с.

21. Хәйретдин А.Г. *Муса Җаруллаһ Бигиев хакында гыйльми хәбәрләрем* // Фәнни докладлар җыентыгы. Казан: Алма-Лит, 2003. 90 б.

22. Бигиев М. Полуночное солнце. Пер. с татаро-осман. Хайрутдинов А.Г. // *Идель*. 2003. № 4. С. 34–41.

23. Хәйретдинов А.Г. Риза Фәхретдин һәм Муса Бигиев// *Ризаэддин Фәхреддин: Мирасы һәм хәзерге заман*. Мәкаләләр җыентыгы. Казан: Изд-во Ин-та истории АН РТ, 2003. С. 279–289.

24. Хәйретдинов А. Муса Җаруллаһ Бигиев (1873–1949). Татар зыялылары: тарихи портретлар: Укытучылар һәм югары сыйныф укучылары өчен мәкаләләр җыентыгы / Төз. Р.М. Мөхәммәтшин. Русчадан Ә.М. Камалов тәрҗ. Казан: Мәгариф, 2003. 144–156 б.

**2004**

25. Гёрмез М. Муса Джаруллах Бигиев. Пер. с турецк. Айдар Хайрутдинов. Казань: Изд-во «Иман», 2004. 193 с.

26. Бигиев Муса. Пост в длинные дни. Перевод Хайрутдинова А. // *Минарет*. 2004. № 3. С. 46–53.

27. Хайрутдинов А.Г. Значение поднятого Мусой Бигиевым вопроса о всеохватности божественного милосердия // *Сб. материалов итоговых конференций молодых ученых Института истории им. Ш. Марджани АН РТ за 2003–2004 годы*. Казань: Изд-во Института истории. С. 329–334.

**2005**

28. Хайрутдинов А.Г. Введение // Бигиев М. Дж. *Избранные труды*. В двух томах. Т. I.: / М. Дж. Бигиев. Сост. и подготовка тома к изданию, перевод с османского, введение и примечания Айдара Хайрутдинова / Антология татарской богословской мысли. Казань: Татарское кн. изд-во, 2005. С. 6–76.

29. Хайрутдинов А. Г. *Муса Джаруллах Бигиев*. Казань: Изд-во «Фэн» АН РТ, 2005. 180 с.

30. Хайрутдинов А. Г. М. Бигиев // *Татарские интеллектуалы: исторические портреты* / Сост. Р. М. Мухаметшин. 2- изд., перераб. и доп. Казань: Магариф, 2005. С. 203–212.

31. Хайрутдинов А. Г. Бигиев Муса // *Большая Российская Энциклопедия*: [в 30 томах]. М.: Большая Российская Энциклопедия, 2004. [Т.]3. 2005. 766 с.

32. Хайрутдинов А. Г. Муса Бигиев о любви, браке и сексе // *Идель*. 2006. № 4. С. 54–57.

**2006**

33. Бигиев М. *Избранные труды*: в 2 т. / Муса Бигиев; Сост и пер. с осман. А. Хайрутдинова. Т. 2: Обращение к Великому Турецкому национальному Собранию, Введение к трактату «Аль-Муафакат», Воззвание к мусульманским нациям, Женщина в свете священных аятов благородного Корана. Казань: Татар. кн. изд-во, 2006. 256 с.

**2007**

34. Хайрутдинов А. Г. Исламское учение о всеохватности божественного милосердия и его значение на современном этапе развития человеческого сообщества // *Религия в современной системе международных отношений: Либерализм и традиционное самосознание. Материалы международной научно-практической конференции*. С.-Петербург, 24 ноября 2006 г. СПб., 2007. С. 147–161.

**2009**

35. Хайрутдинов А. Г. Арабская литература и исламские науки // *Современный ислам*. 2009 (1430). № 2–3, февраль. С. 68–73.

36. Хайрутдинов А. «Государственная дума и вопрос о кремации» // *Ислам в Санкт-Петербурге.* Энциклопедический словарь. Серия «Ислам в Российской Федерации». Вып. III. М. Нижний Новгород: ИД «Медина», 2009. С. 66.

37. Хайрутдинов А. «Замечание» // *Ислам в Санкт-Петербурге*. Энциклопедический словарь. Серия «Ислам в Российской Федерации». Вып. III. М. Нижний Новгород: ИД «Медина», 2009. С. 79.

38. Хайрутдинов А. «История Корана и его списков» // *Ислам в Санкт-Петербурге*. Энциклопедический словарь. Серия «Ислам в Российской Федерации». Вып. III. М. Нижний Новгород: ИД «Медина», 2009. С. 93.

39. Хайрутдинов А. «Маленькие мысли по большим вопросам» // *Ислам в Санкт-Петербурге*. Энциклопедический словарь. Серия «Ис-

лам в Российской Федерации». Вып. III. М. Нижний Новгород: ИД «Медина», 2009. С. 125.

40. Хайрутдинов А. «Основы шариата» // *Ислам в Санкт-Петербурге*. Энциклопедический словарь. Серия «Ислам в Российской Федерации». Вып. III. М. Нижний Новгород: ИД «Медина», 2009. С. 177.

41. Хайрутдинов А. «Религиозный налог – закят» // *Ислам в Санкт-Петербурге*. Энциклопедический словарь. Серия «Ислам в Российской Федерации». Вып. III. М. Нижний Новгород: ИД «Медина», 2009. С. 200.

42. Гермез М. Муса Джаруллах Бигиев: Учебно-методические и научные материалы для составления учебных пособий, курсов лекций, хрестоматий, а также научно-исследовательской работы студентов. Казань: Изд-во ДУМ РТ, 2009. 167 с.

**2010**

43. Гёрмез М. *Муса Джаруллах Бигиев* / Перевод с турец.: Хайрутдинов А.Г. Казань: Российский исламский ун-тет, 2010. 169 с.

**2011**

44. Хайрутдинов А. *Исламское обновление как условие прогресса: Социально-философское исследование наследия Мусы Джаруллаха Бигиева*. LAP LAMBERT Academic Publishing GmbH & Co. KG. Saarbrücken, GERMANY. 2011. 228 с.

45. Хәйретдинов А.Г. Муса Җаруллаһ мирасында хатын-кыз мәсьәләсе // *Фәнни Татарстан*. 2011.153–164 б.

**2014**

46. Бигиев М.Д. *Избранные труды* [сост. и пер. с османского яз., введ., сн. и коммент. А. Хайрутдинова]. Казань: Татар.кн. изд-во, 2014. 398 с.

**2015**

47. «Муса Бигиев: Хиджаб в благородном Коране» / Из книги «Женщина в свете аятов Благородного Корана» Бигиев М. Избранные труды в 2 т. Сост. и пер. с осман. А. Хайрутдинова. Т. 2. Казань: Татар. кн. изд-во, 2006. С. 173–178. // *Медина аль-ислам*. 2015. № 2 (160) февраль.

48. Хайрутдинов А.Г. «Учение Мусы Бигиева о всеохватности божьей милости как основа воспитания культуры межнационального и межконфессионального общения» // *Взаимодействие органов власти, общественных объединений и образовательных учреждений по гармонизации этноконфессиональных и межнациональных отношений: региональный аспект: сб. научных трудов Международной научно-практической конференции* (Казань, 29 апреля 2015 г.) / под ред. Г.Ж. Фахрутдиновой. Казань: РИЦ «Школа», 2015. С. 336–339.

49. Хайрутдинов А.Г. М. Бигиев об обновлении мусульманской правовой системы // *Бигиевские чтения: богословская мысль российских*

*мусульман XIX – начала XX вв.*: Сб. научных статей / Сост. И. А. Зарипов, общ. ред. Д. В. Мухетдинов. М.: ИД «Медина», 2015. С. 73–84.

50. Хайрутдинов А. Г. Муса Бигиев: ислам как условие прогресса // *История мусульманской мысли в Волго-Уральском регионе*: учеб. пособие / Под ред. Л. И. Алмазовой, Г. Г. Идиятуллиной, А. Г. Хайрутдинова. Казань: Изд-во Казан. Ун-та, 2015. С. 327–344.

**2016**

51. Хайрутдинов А. Г. Анализ перевода Д. Богуславским седьмого аята суры «Фатиха» и его корреляция с учением М. Бигиева о всеохватности божьей милости // *II Бигиевские чтения – 2015. Мусульманская мысль в XXI веке: единство традиции и обновления*: материалы II Международной науч-образовательной конф., г. Санкт-Петербург, 15–17 мая 2015 г. / [редкол.: Д. В. Мухетдинов (пред.), Ш. Р. Кашаф (отв. ред.) и др.]. Москва: ООО «Изд-кий дом «Медина», 2016. С. 92–99.

52. М. Бигиев. Доказательства Божественного милосердия. (Бигиев М. Рэхмэт илаһия борһаннары. Оренбург: Вакыт, 1911. Перевод со старотатарского А. Г. Хайрутдинова (первая публикация: Бигиев М. Доказательства божественного милосердия / Бигиев М. Избранные труды. В двух томах. Т. 1. Казань: Татар. кн. изд-во, 2005. С. 77–130) // *Исламская мысль: традиция и современность. Религиозно-философский ежегодник. Вып. I* [редкол.: Д. В. Мухетдинов (пред.), Д. З. Хайретдинов (гл. ред.), С. Ю. Бородай (отв. ред.) и др.]. Москва: ООО «Изд-кий дом «Медина», 2016. С. 131–188.

53. Хәйретдинов (Хайрутдинов) А. Г. *Русиядән, димәк мөмкин, йалңыз бән… (Муса Бигиевнең 1927 елгы хаҗнамәсе)*. Тарихи-документаль очерк. Кереш сүз Ә. Т. Сибгатуллина. Казан: ТФА Ш. Мәрҗани ис. Тарих институты, 2016. 156 б.

54. Хәйретдинов А. Г. Муса Җаруллаһ Бигиевнең куен дәфтәрләре // *Әнвәр Хәйри укулары: Милли-мәдәни мирасны барлау, өйрәнү һәм пропагандалау юлында. Республика фәнни-гамәли конференциясе материаллары (Казан, 2015 ел, 27 ноябрь)*. Казан: ТР ФАнең Ш. Мәрҗани ис. Тарих институты, 2016. 107–110 б.

55. Хәйретдинов А. Муса Бигиевнең хаҗнамәсе // *Гасырлар авазы / Эхо веков*.– 2016. № 3/4 (84/85). С. 198–207.

56. Хайрутдинов А. Г. Хаджнаме Мусы Бигеева. «Из России, можно сказать, я один…» // *Ислам в современном мире*. 2016. № 3. С. 25–50; № 4. С. 25–44.

**2017**

57. Хәйретдин А. Патшалар да сәлам биргән, киңәш сораган галим // *Ватаным Татарстан*. 2017. № 4, 13 гыйнвар.

58. Айдар Хайрутдинов. Муса Бигеев: «Искатель истины затыкает уши и открывает глаза» // *Казань*. 2017. № 2. С. 84–86.

59. Айдар Хайрутдинов. *Философия божьей милости в трудах Мусы Джаруллаха Бигеева*. Saarbrüken: LAP LAMBERT Academic Publishing RU, 2017. 154 с.

60. Хайрутдинов А. Г. Сущность и содержание веры с точки зрения Мусы Бигеева // *Ислам в современном мире*. 2017. № 13(2). С. 73–90.

61. Хәйретдинов А. Г. *Муса Бигиевнең «Халык назарына» исемле китабының аңлатмалы тәрҗемәсе*. Казан, 2017. 136 б.

62. Бигиев М. Вера. Перевод с татаро-османского и примечания Хайрутдинов А. Г. // Исламская мысль: традиция и современность. Религиозно-философский ежегодник. Вып. 2 [редкол.: Д. В. Мухетдинов (гл. ред.), С. Ю. Бородай (отв. ред.) и др.]. Москва: ООО «Изд-кий дом «Медина», 2017. С. 185–201.

63. Хәйретдинов А. Г. Муса Бигиевнең куен дәфтәрләрендә XX йөзнең беренче чиреге Якын Көнчыгыш тарихы // *Татарское рукописное наследие: изучение и сохранение: материалы всероссийской научно-практической конференции, посвященной 130-летию С. Вахиди* / сост.: Л. Ш. Гарипова, Д. З. Марданова; под ред. И. Г. Гумерова. Казань: ИЯЛИ, 2017. С. 187–194.

64. Хайрутдинов А. Уникальные записи Мусы Бигеева о его хадже 1927 года // *Хадж российских мусульман*. 2017. № 8. С. 7–14.

65. Хайрутдинов А. Г. Хадж-наме Мусы Бигеева. Муса Бигиевнең 1927 нче елгы хаҗнамәсе (хәзерге татар теленә тәрҗемә) // *Хадж российских мусульман*. 2017. № 8. С. 15–53.

66. Хәйретдинов А. Гыйбрәтле сәфәр. Муса Бигиев эзләре кая илтә? // *Ватаным Татарстан*. 2017. № 192, 23 декабрь.

**2018**

67. Хайрутдинов А. Г. Муса Бигиевнең «Халык назарына берничә мәсьәлә» исемле китабының татар теленә тәрҗемә итү тәҗрибәсе турында // *Тюркский мир и исламская цивилизация: проблемы языка, литературы, истории и религии: IX Международная тюркологическая конференция (Россия, РТ, г. Елабуга, 13–14 апреля 2018 г.)* отв. ред. Р. Б. Камаева. Казань: Изд-во Казан. ун-та, 2018. 295–298 б.

68. Хәйретдинов Айдар. *Муса Бигиевнең азык төлектә хәлал вә хәрам мәсьәләләренә карашы*. Казан: Казан инновацион ун-ты, 2018. 46 б.

69. Хайрутдинов А. Г., Ибрагимов Р. Р. Письменное наследие Мусы Джаруллаха Бигеева: находки, наличное и искомое // *Ислам в современном мире*. 2018. № 14(2). С. 43–60.

70. Хайрутдинов А. Г. Республиканская Турция в дневниковых записях Мусы Бигеева // *Minbar. Islamic Studies*. 2018. № 11(1). С. 15–28.

71. Хәйретдинов А. Г. *Муса Бигиевнең хаҗнамәсе*. Казан: ТФА Ш. Мәрҗани ис. Тарих институты, 2018. 208 б.

72. Хайрутдинов А. Г. Мусульманский Восток 20-х годов XX века в дневниках Мусы Бигеева // *Minbar. Islamic Studies*. 2018. № 11(2). С. 211–220.

73. Хәйретдинов Айдар. Муса Бигиев: «Киләчәк – исламиятнеке» // *Безнең мирас*. 2018. № 10. С. 58–61.

74. А. Г. Хәйретдинов. М. Бигиевнең «Маидә» әсәренең татар теленә тәрҗемәсендә «қ» һәм «ғ» графемаларын куллану үзенчәлекләре һәм проблемалары // *Сохранение и развитие родных языков в условиях многонационального государства: проблемы и перспективы*: *материалы Международного научно-практического форума*. Казань: Изд-во Казан. ун-та, 2018. С. 222–224.

75. Хайрутдинов А. Г. «Маида»: малоизвестный богословско-правовой трактат Мусы Бигеева // *Ислам в современном мире*. 2018. № 14(4). С. 125–130.

76. Бигеев М. Д. Трапеза // *Ислам в современном мире*. 2018. № 14(4). С. 131–148.

77. Хайрутдинов А. Г. В поисках наследия Мусы Бигиева: доступное и искомое // *Minbar. Islamic Studies*. 2018. № 11(3). С. 608–618.

78. Хайрутдинов А. Г. Рукописный перевод Корана Мусы Бигеева: новые свидетельства и направления дальнейшего поиска // *Minbar. Islamic Studies*. 2018. № 11(4). С. 805–818.

79. Хәйретдинов А. Г. Муса Бигиев: ислам – алгарыш шарты // *Идел-Урал төбәгендә мөселман фикере тарихы: уку әсбабы*. Казан: Болгар ислам академиясе, 2018. 287–304 б.

**2019**

80. Хайрутдинов А. Г. «Маида»: трактат Мусы Бигеева о дозволенном и запретном в пище мусульманина // *Ислам в современном мире*. 2019. № 15(1). С. 33–46.

81. Бигеев М. Д. Трапеза (продолжение) // *Ислам в современном мире*. 2019. № 15(1). С. 47–68.

82. Хайрутдинов А. Он ссылается на Коран и Сунну // *Sohbet. 2019.* № 7. С. 22–25.

83. Хайрутдинов А. Г. Муса Бигиев и новая философия исламской правовой науки // *Исламская мысль: традиция и современность. Религиозно-философский ежегодник.* Вып. 3 / [редкол.: Д. В. Мухетдинов (пред.), Д. З. Хайретдинов (гл. ред.), С. Ю. Бородай (отв. ред.) и др.]. Москва: ООО «Изд-кий дом «Медина», 2018. С. 171–190.

84. Хайрутдинов А. Г. Муса Бигиев о проблеме пьянства сквозь призму Торы, Илиады и Корана. // *IX Международная проблемно-методологическая конференция Письменные памятники Востока: проблемы*

*перевода и интерпретации*. 28–30 октября 2019 г. Тезисы и конспекты докладов. М.: ИВ РАН, 2019. С. 72–74.

85. Хәйретдинов А. Г. Муса Бигиев тормышының соңгы еллары. Япония-Һиндыстан-Төркия-Мисыр // *Научное наследие и общественная деятельность братьев Максуди. Материалы Международной научной конференции, приуроченной к 150-летию А. Максуди и 140-летию С. Максуди* (Казань, 7 декабря 2018 г.). Казань: Институт истории им. Ш. Марджани АН РТ, 2019. С. 376–403.

86. Хайрутдинов А. Г. *Письменное наследие Мусы Джаруллаха Бигиева*: монография. Казань: Институт истории им. Ш. Марджани АН РТ, 2019. 188 с.

87. Бигиев М. Җ. *Аш табыны* / М. Җ. Бигиев: госманлы-татар теленнән тәрҗ. А. Г. Хәйретдинов; кереш сүз А. Г. Хәйретдинов; кереш сүз А. В. Тимирясова, Е. Л. Яковлева. Казан: Казан инновацион ун-тының «Познание» нәшр., 2019. 6–20 б.

88. Хайрутдинов А. Г. «Маида»: богословский трактат Мусы Бигиева // Бигиев М. Д. *Мусульманская трапеза* / М. Д. Бигиев: пер. с татаро-османского яз., предисл. А. В. Тимирясовой, Е. Л. Яковлевой; предисл. А. Г. Хайрутдинова. Казань: Изд-во «Познание» Казанского инновационного ун-та, 2019. 6–20 с.

89. М. Бигиев. Основы шариата (фрагмент) / Перевод с татаро-османского и примечания А. Г. Хайрутдинова // *Исламская мысль: традиция и современность. Религиозно-философский ежегодник*. Вып. 4 / [редкол.: Д. В. Мухетдинов (гл. ред.), С. Ю. Бородай (отв. ред.) и др.]. М.: ООО «Изд-кий дом «Медина»», 2019. С. 219–240.

**2020**

90. Хайрутдинов А. Г. Междисциплинарное исследование Мусы Бигиева о понятии «йаджудж-маджудж» // *Minbar. Islamic Studies*. 2020. № 13(1). С. 117–134.

91. Хайрутдинов А. Г. Прижизненные корановедческие публикации Мусы Бигеева в турецком журнале «Yeni Selâmet» // *Ислам в современном мире*. 2020. № 16(1). С. 43–60.

92. Хәйретдинов А. Г. Муса Җаруллаһ (Ярулла углы Муса Бигиев): тормыш юлы һәм мирасы // *Туган җир*: Төбәк тарихы буенча журнал [Родной край: Краеведческий журнал]. 2020. № 3–4. 341–360 б.

93. Хайрутдинов А. Г. Критический отзыв М. Бигиева на книгу Ризаэддина Фахреддина «Религиозные и социальные проблемы» // *Историческая этнология*. 2020. Т. 5, № 2. С. 269–283.

94. Хайрутдинов А. Г. Из истории туркестанской эмиграции: «Туркестанское благотворительное общество» в Каире // *Minbar. Islamic Studies*. 2020. № 13(4). С. 824–844.

95. Хайрутдинов А. Г. Муса Бигиев и татарское общественно-политическое движение в 1905–1917 годах // *Из истории и культуры народов Среднего Поволжья*. 2020. Т. 2. № 10. С. 112–122.

96. Хайрутдинов А. Г. Турецкая тема в творческом наследии и деятельности Мусы Джаруллаха Бигиева // *Тюркологические исследования*. 2020. Т. 3, № 3. С. 60–68.

**2021**

97. Хайрутдинов А. Г. Научное наследие Мусы Бигиева // *II Международный форум «Богословское наследие мусульман России»*. Сб. научных докладов конференций. Сост.: Д. М. Абдрахманов [и др.]. Казань, 2021. С. 117–126.

98. Бигиев, Муса. *Доказательства Божьей милости* / под общ. ред. Д. В. Мухетдинова; пер. с тат.-осман. и примеч. А. Г. Хайрутдинова. Серия: «Исламская мысль в России: возрождение и переосмысление». М.: ИД «Медина», 2021. 136 с.

99. Бигиев, Муса. Взгляд на верование людей в божественное / под общ. ред. Д. В. Мухетдинова; пер. с тат.-осман. и примеч. А. Г. Хайрутдинова. Серия: «Исламская мысль в России: возрождение и переосмысление». М.: ИД «Медина», 2021. 48 с.

100. Хайрутдинов А. Г. Общественно-политическая деятельность Мусы Бигиева и ее туркестанская составляющая в письмах к Энверу-паше // *Ислам в современном мире*. 2021. № 17(3). С. 145–164.

101. Хайрутдинов А. Г. Учение о всеохватной божьей милости как основа нового мусульманского дискурса в диалоге цивилизаций // *Мусульмане в Европе. Сосуществование, взаимодействие, межцивилизационный диалог = Moslems in Europe. Coexistence, cooperation, dialogue of civilizations*: [монография] / [отв. ред. А. К. Камкин]. М.: Ин-т Европы РАН, 2021. 158 с.

102. Айдар Хайрутдинов. Проблемы перевода татаро-мусульманской религиозной литературы на современный татарский язык: лексико-семантический аспект (на материалах наследия Мусы Бигеева) // *Культурные, экономические, технологические контакты и взаимодействие Японии и Татарского мира: история и современность*: сб. научных трудов. Вып. III. Казань: Институт истории им. Ш. Марджани АН РТ, 2021. 272 С. 229–237.

**2022**

103. Бигиев, Муса. *Доказательства Божьей милости* / под общ. ред. Д. В. Мухетдинова; пер. с тат.-осман. и примеч. А. Г. Хайрутдинова. Серия «Исламская мысль в России: возрождение и переосмысление». М.: ИД «Медина», 2022. 160 с.

104. Бигиев, Муса. *Взгляд на верование людей в божественное* / под общ. ред. Д. В. Мухетдинова; пер. с тат.-осман и примеч. А. Г. Хайрутдинова. Серия «Исламская мысль в России: возрождение и переосмысление». М.: ИД «Медина», 2022. 64 с.

105. Бигиев, Муса. *Трапеза* / под общ. ред. Д. В. Мухетдинова; пер. с тат.-осман., вступ. слово и примеч. А. Г. Хайрутдинова. Серия «Исламская мысль в России: возрождение и переосмысление». М.: ИД «Медина», 2022. 132 с.

106. Бигиев, Муса. *Проблема кремации, озвученная в Государственной думе* / под общ. ред. Д. В. Мухетдинова; пер. с тат.-осман. и примеч. А. Г. Хайрутдинова. Серия «Исламская мысль в России: возрождение и переосмысление». М.: ИД «Медина», 2022. 64 с.

107. Бигиев, Муса. *Некоторые актуальные проблемы нашего общества* / под общ. ред. Д. В. Мухетдинова; пер. с тат.-осман. и примеч. А. Г. Хайрутдинова. Серия «Исламская мысль в России: возрождение и переосмысление». М.: ИД «Медина», 2022. 200 с.

108. Муса Бигиев. *Тәсхыйх рәсми хатти Коръән* (Коръәннең язылыш сурәтен дөресләү) / ис. тат. тел. тәрҗемә, кер. сүз, астөшерм. һәм аңлатм. Р. Р. Ибрагимов. Фәнни һәм әдәби мөхәррир: А. Хәйретдинов. Мәскәү: АНО Изд-кий дом «Йосеф Ибрахим», 2020. 152 б.

109. Айдар Хайрутдинов. Цель жизни – образование нации. Почему Муса Бигиев стал проповедником теории обновления // Татарстан. 2022. № 5. С. 34–35.

110. Айдар Хәйретдинов. Тормыш максаты – милләтне белемле итү. Ни өчен Муса Бигиев яңарыш теориясе хатыйбы була // Татарстан. 2022. 33–34 б.

111. Хәйретдинов А. Г. Муса Бигиевнең әсәрләрен татар теленә тәрҗемә итү тәҗрибәсе һәм хәзерге татар әдәби теле / Опыт перевода произведений Мусы Бигиева на татарский язык и современный татарский литературный язык // *Ислам в России: история, культура, экономика: XI Международная тюркологическая конференция (г. Елабуга, 13 мая 2022 года)* / Отв. ред. А. З. Нигамаев. Казань: Изд-во Казан. ун-та, 2022. С. 319–322.

112. Хайрутдинов А. Г. Общественная деятельность Фаузии Ибрагимовой // *Minbar. Islamic Studies*. 2022. № 15(2). С. 303–324.

113. Бигиев, Муса. *Мускират: проблема опьяняющих напитков с точки зрения исламского шариата* / под общ. ред. Д. В. Мухетдинова; пер. с тат.-осман. и примеч. А. Г. Хайрутдинова. Серия «Исламская мысль в России: возрождение и переосмысление». М.: ИД «Медина», 2022. 160 с.

# Эчтәлек

Кереш сүз . . . 3

***I бүлек. Муса Җаруллаһның тәрҗемәи хәле, эшчәнлеге һәм әсәрләре***

Беренче фасыл: Муса әфәнденең гаиләсе, фамилиясе; балачагы һәм яшьлеге . . . 14
Муса Җаруллаһ биографиясенең хронологик бүленеше . . . 22
Нурлы Казан вә Бохара-и Шәрифәдә . . . 23
Русиядән Госманлы дәүләтенә. Муса Акъегетзадә белән көрәшү . . . 30
Мисыр, Хиҗаз вә Һиндестанга сәфәр . . . 32
Гыйлем сәфәренең нәтиҗәләре . . . 36
Икенче фасыл: 1904–1916 елларда Русиядәге тормышы . . . 38
Туган иленә кайту. Өйләнүе . . . 38
Беренче китабы . . . 42
Габдерәшит Ибраһим белән танышу. «Өлфәт», «Әт-Тилмиз» . . . 44
Мөселман корылтайларында эшчәнлеге . . . 48
Казан: 1907–1909 еллар. Яңа китаплары. Әхмәт-Зәки Вәлиди . . . 56
Коръәндәге хаталарны төзәтү мәсьәләсе . . . 69
Оренбург: «Хөсәения» мәдрәсәсендәге вакыйгалар . . . 76
Гыйлеме һәйәт, ягъни астрономиягә караган хезмәте . . . 95
Фикъһыга караган хезмәте . . . 109
Финляндиягә беренче сәяхәте . . . 122
Фарсы шигъриятеннән тәрҗемә. . . . 124
Аллаһ мәрхәмәтенең гомумилеге турындагы хезмәтләре . . . 129
Бәрәкәтуллаһ белән көрәшүе . . . 131
Финляндиягә икенче сәяхәте. Баемаган кояшны күзәтү . . . 134
Муса Җаруллаһ һәм Габдулла Тукай . . . 136
Коръән тәрҗемәсе . . . 142
Төркиядә китапларының тыелуы . . . 150
Гаяз Исхакый белән уртак эшчәнлек . . . 152
Русия һәм Төркия матбугатында Муса әфәнденең исеме . . . 154
«Әманәт» нәшрияты һәм гыйльми эшчәнлек . . . 160
Инкыйлаб алды еллары . . . 180
Өченче фасыл: 1917–1930 еллар: Совет хакимияте астында . . . 196
Февраль инкыйлабыннан соң . . . 196
Мәскәү: I Бөтенрусия мөселман корылтае . . . 204
Казан: II Бөтенрусия мөселман корылтае. . . . 208
Большевиклар түнтәрелеше һәм вәхшәтнең беренче чаткылары . 211
«Шәригать әсасләре». . . . 217
Афәт еллары. . . . 221
Яңадан Бәрәкәтуллаһ һәм Ленин белән көрәшү . . . 224
Шәйхелислам Мостафа Сабри тарафыннан тәнкыйть . . . 226

Әнвәр-паша белән танышуы һәм Шәрык халыкларының
Беренче корылтае . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 229
Бохара белән Ташкентта. Беренче тоткарлану. . . . . . . . . . . . . . . 235
Исмәгыйль Сойсаллы һәм «Төркия бөек милләт мәҗлесенә
мөрәҗәгать» . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 238
Петроградта иҗтимагый эшчәнлек . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 241
«Русия мөселманнарының мәдәни дәүләтләргә мөрәҗәгатьләре» 243
«Русия мөселманнарының мәдәни дәүләтләргә мөрәҗәгатьләре» 244
Качып китмәвенең сәбәпләре . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 249
«Ислам милләтләренә» исемле китабы һәм икенче тоткарлану . . . 250
Сөргендә. Галимҗан Ибраһимовның һөҗүме . . . . . . . . . . . . . . 264
1926 ел: Бөтендөнья мөселман корылтайлары. . . . . . . . . . . . . . 272
Муса әфәнденең хаҗга баруы. Куен дәфтәрләре. . . . . . . . . . . . . 278
Упкын өстендә . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 283
Дүртенче фасыл: Горбәттә үткәргән еллары. . . . . . . . . . . . . . . 285
Илдән качып китүе. Шәркый Төркестан . . . . . . . . . . . . . . . . . 285
Әфганстанда кырык көн. Мисыр һәм Бөтендөнья мөселман
конгрессында. . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 287
Таһир Хәлиминең хатирәләре. . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 291
Берлиндагы нәшрияты һәм анда басылырга тиешле китаплары. . . 294
Беренче Төрек тарих конгрессында. . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 303
Яңадан Хиҗазда. Гобәйдулла әс-Синһди. . . . . . . . . . . . . . . . . . 307
Яңа нәшрият, яңа китаплар. . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 312
Хатын-кызга мәдхия . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 329
Шигыйлар дөньясына сәфәр. . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 333
Яңадан Мисырда . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 341
Китапларын гарәп телендә язу. Артур Җеффери . . . . . . . . . . . . . 343
Яңадан Һиндестанда . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 351
Япониягә сәяхәт . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 354
Муса әфәнденең шәкерте Тошихико Изутсу. . . . . . . . . . . . . . . . 357
Яңа Җиһан сугышы. Һиндестан тозагы. Хәмидулла-Хан . . . . . . . . 363
Җиһан сугышыннан соң. Йосыф Уралгирәй. Әхмәт Бигиев . . . . . 369
Соңгы мәртәбә Төркиядә (сентябрь 1947 – декабрь 1948). . . . . . . 375
Бишенче фасыл: Гомеренең соңгы елы һәм вафаты . . . . . . . . . . . 390
Төркиядән китүенең сәбәбе – Коръән тәрҗемәсе. . . . . . . . . . . . . 390
Гомеренең Каһирәдә үткәргән соңгы айлары (декабрь
1948 – октябрь 1949). . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 397
Муса әфәнденең соңгы көне . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 415
Йомгак урынына . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 423

***II бүлек. Муса Бигиевнең искә алынган китапларының нәшер ителү тәртибендә төзелгән исемлеге***

## *III бүлек. Муса әфәнденең китапларыннан өзекләр, кайбер хезмәтләре, документлар һәм хатлар*

Тарихи мәҗлес . . . . . 437
«Әл-Мөвафәкать»нең нәшер ителүенә кагылышлы бер ике сүз . . . . . 447
«Рәхмәт илаһийә борһанлары»ннан . . . . . 465
Сәхәр кояшы . . . . . 473
Әдәбиятыбызның киләчәге . . . . . 495
**وَخَسَفَ الْقَمَرُ وَجُمِعَ الشَّمْسُ وَالْقَمَر** . . . . . 525
«Я, было, огорчился, но теперь понял» . . . . . 537
«Мой взгляд на исламский Шариат» . . . . . 550
«Почему Запад когда прогрессировал, а мир Ислама шел к упадку?» . . . . . 563
«Могъҗиза» . . . . . 570
«Дини мәктәбләр, мәдрәсәләр хакында мөляхәзалар» . . . . . 597
«Шәригать әсасләре» исемле китаптан . . . . . 603
«Бүгенге мөһим хаҗәтләргә күрә тәдбир була алачак маддәләр» . . . . . 614
Муса Җаруллаһның Әнвәр-пашага язган хаты . . . . . 628
«Обращение к Великому Турецкому Национальному Собранию» . . . . . 638
Китап бисмилласы . . . . . 653
«Заключение» . . . . . 690
«Мөскират» китабыннан: Сүз бисмилласы . . . . . 697
Муса әфәнденең Зиннәт Бүрегә язган хаты . . . . . 707
Кыйраәт тарихы . . . . . 713
«Йа́җүҗ» китабыннан . . . . . 720
Ислам әсәрләрендә Йаҗүҗ . . . . . 720
Әгәр Йаҗүҗ төрек булса . . . . . 724
«Хатун» китабыннан . . . . . 727
Ханымнарга ихтирам белдерү йөзеннән . . . . . 727
Бер бөек ислам шагыйренең хатын-кызлар хакында гакыйдәсе . . 740
Финляндиягә язган хатларыннан . . . . . 747
Коръән кәрим тәрҗемәсе . . . . . 751
Маъидә . . . . . 764

## *IV бүлек. Чыганаклар һәм әдәбият*

I. Чыганаклар . . . . . 813
II. Әдәбият . . . . . 819
III. Авторның Муса Бигиевкә кагылышлы хезмәтләренең исемлеге . . . . . 820

16+ Знак информационной продукции согласно
ФЗ от 29.12.2010 г. №436-ФЗ

Научно-популярное издание

**Хайрутдинов Айдар Гарифутдинович**

**Муса Ярулла Бигиев**

Ответственный за выпуск: *Фуат Рафиков*
Художественное оформление: *Рамиль Миннуллин*
Дизайн обложки: *Григорий Эйдинов*
Корректор: *Зульфия Мустафина*

Формат 84x108 1/32. Усл. печ. листов 43,68
Бумага офсетная. Тираж 1500 экз. Заказ №

Оригинал-макет подготовлен с помощью
пакета программ Jahat™.

Отпечатано в полном соответствии с качеством
предоставленного электронного оригинал-макета в типографии
филиала ОАО «ТАТМЕДИА» ПИК «Идел-Пресс».
420066, г. Казань, ул. Декабристов, 2. e-mail: idelpress@mail.ru

9 785902 783558



**Муса Бигиев. 1893**



**Муса әфәнденең әнисе**
**Фатыйма ханым.**
**А. Таһирҗанова архивыннан**



**Әл-Әзһәр дарелфөнүнендә укыган еллар.**
**Уңнан беренче – Муса Бигиев**



Муса әфәнде белән Әсма-Галия туташның бер-берсенә җибәргән фотосурәтләре. А. Таһирҗанова архивыннан



Муса әфәнде (икенче рәттә сулдан икенче) Русия мөселманнарының 3 нче корылтае президиумында. 16 август, 1906



**Муса әфәнде. 1909**


تاريخ القرآن و المصاحف

(تأليف)

موسى جار الله روستوفدونى.

«Тариху әл-Коръәни вә әл-мәсахифи» исемле китабы. 1904


فيلسوف امام كبير ابى العلاء المعرى حضرتلرينك

اللزوميات

موسى بيگييف قلميله.

ناشرى:

КАЗАНЬ.
ЭЛЕКТРО-ТИПОГРАФІЯ ШАРАФЪ
1907.

«Әл-Лөзүмийәт» китабы. 1907


موسى بيگييف.

رحمت الهيه برهانلرى

ناشرى:

شرق كتبخانه سى

اورسكى.

Айдар Хәйретдинов
китапханәсе

ТИП. ГАЗ. „ВАКТЪ" ВЪ ОРЕНБУРГѢ
1911

«Рәхмәт илаһия борһанлары» китабы.1909


خلق نظرينه

برنيچه مسئله

ناشرى:

محمدعليم افندى مقصودوف.

КАЗАНЬ.
Электро-типографія „УМИДЪ"
1912.

«Халык назарына берничә мәсьәлә» китабы. 1912



موسى جارالله

بويوك موضوعلرده

اوفاق فكرلر

كتابك مندرجاتى

Тип. М-А. Максутова. СПБ.

«Бөек мәүзугларда уфак фикерләр» китабы. 1914



اسلام ملتلرينه

شانلى تورك عسكرى

«Ислам милләтләренә» («Исламият әлифбасы») китабы. Берлин, 1923



شريعت اسلاميه نظرنده

مسكرات مسئله لرى

موسى جارالله

محمود بك مطبعه سى

١٩٢٧

«Шәригать исламийә назарында мөскират мәсьәләләре» китабы. Истанбул, 1927



شريعت اساسلرى

Петроградъ.

Типографія М-А. Максутова

1917

«Шәригать әсасләре» китабы. 1917



**Муса әфәнде, Әсма-Галия ханым һәм аларның кызлары Мәрьям белән Зәйнәп. 1908. А. Таһирҗанова архивыннан**



Муса әфәнде.
1910 еллар уртасы



Муса әфәнде белән
Әсма-Галия ханым. 1912.
А. Таһирҗанова архивыннан



Әсма-Галия ханым балалары белән. Сулдан уңга: Мөхәммәт, Әхмәт, Һинд, Мәрьям, Зәйнәп. Чистай, 1912.
А. Таһирҗанова архивыннан



**Муса әфәнденең китапла-
рын ясаклаган шәйхелислам
Мөхәммәт Әсад әфәнде**



**Муса әфәнде инкыйлаблар
дәверендә**




**Шәйхелислам Мостафа Сабри һәм аның «Дини мөҗәддидләр»
исемле китабының гонваны**



**Күренекле татар җәмәгать эшлеклеләре. 1 нче рәттә сулдан уңга: Фатих Кәрими, Һади Максуди, Вәлиәхмәт Хәким, Муса Бигиев; икенче рәттә уңнан беренче Гыймад Җамалетдин.1917. Ф. Насретдин архивыннан**



**Ачлык еллары. Лотфулла Кумысниковның өендә**



**Уфада үткәрелгән Голәмалар һәм мөхтәсибләр корылтаенда. Икенче рәттә уңнан икенче Муса Бигиев, бишенче Ризаэддин Фәхреддин, сулдан икенче Хәсәнгата Габәши; өченче рәттә сулдан өченче Габдрахман Гомәри. 1923**



**Мәскәүдә Әсадуллаев йортында җирле татарлар белән. Сөргенлек еллары, 1923–1926**



**Мәккә мөселман корылтаеның Советлар Берлеге делегатлары белән. 1926**



**Гаиләсе белән. Ленинград, 1927**



Токио, 1938–1939.
Д. Усманова архивыннан



Муса Җаруллаһ Япониядәге татар мөһаҗирләреннән Әхдәм Әхмәтов белән Фуҗийамә тавы хозурында. Али Мәртхан Дүндәр архивыннан



Әфганстан әмире Әманулла Хан белән Ленинград мәчетендә. 1928



1929–1933 елларда хакимлек иткән Әфганстан патшасы Мөхәммәд Надир Шаһ



Муса әфәнде.
1920 еллар ахыры



Уңнан сулга: Муса Бигиев, имам Шамилнең оныгы Сәед Шамил, Гаяз Исхакый Әл-Кодестә үткәрелгән Бөтендөнья ислам корылтаенда. 1931, декабрь



**Муса әфәнде (икенче рәттә сулдан беренче) дуслары белән. Беренче рәттә сулдан икенче М. Чокай, дүртенче Рәшит Рәхмәти Арат, икенче рәттә уңнан икенче Гаяз Исхакый, аның янында кызы Сәгадәт Чагатай. Берлин, 8 октябрь, 1932.**
**Исмәгыйль Төрекоглу архивыннан**



**Финляндия татарлары белән.**
**Муса әфәнде беренче рәттә уңнан өченче. 1932–1933**



Муса Бигиев белән Япониядәге татар мөһаҗирләреннән Габделхәй Корбангалиев. 1938–1940. Али Мәртхан Дүндәр архивыннан



Муса әфәнденең шәкерте Тошихико Изутсу



Гобәйдулла әс-Синдһи хәзрәтләре



Принсес Хәдиҗә Габбас Хәлим



Мәүләна Бәрәкәтуллаһ Сахиб



Муса әфәнденең дусты Зиннәтулла Әхсән Бүре



Бһопал нәүвабы Хәмидулла Хан



**Муса әфәнденең соңгы фотосурәтләреннән берсе. 1948**